КОРЪӘН-КӘРИМ ЯКТЫСЫНДА

# ПӘЙГАМБӘРЛӘР ТАРИХЫ

Осман Нури ТОПБАШ

ИЗДАТЕЛЬСТВО
«ЭРКАМ»

بسم الله الرحمن الرحيم

ИСТАНБУЛ
2023

**© Издательство Эркам - Истанбул: 2023 / 1444** по хиджре

# ПӘЙГАМБӘРЛӘР ТАРИХЫ

Осман Нури ТОПБАШ


| | |
|---|---|
| **Перевод с оригинала:** | Kur'ân-ı Kerîm Işığında Nebîler Silsilesi serisi |
| **Автор:** | Осман Нури Топбаш |
| **Перевод с турецкого и редактирование:** | Абдуррауф Абдулкадыр улы Забиров |
| **Дизайн:** | Расим Шакироглу |
| **ISBN:** | 978-625-440-552-5 |
| **Адрес:** | İkitelli Organize Sanayi Bölgesi Mahallesi, Atatürk Bulvarı, Haseyad 1. Kısım No:60/3-C Başakşehir, Истанбул, Төркия |
| **Тел:** | (+90-212) 671-0700 pbx |
| **Факс:** | (+90-212) 671-0748 |
| **Электронная почта:** | info@islamicpublishing.org |
| **Веб-сайт:** | www.islamicpublishing.org |
| **Издано:** | Типография ЭРКАМ |
| **Language:** | Kazan Tatar |

ИЗДАТЕЛЬСТВО «ЭРКАМ»

**КОРЪӘН-КӘРИМ ЯКТЫСЫНДА**

# ПӘЙГАМБӘРЛӘР ТАРИХЫ

Осман Нури ТОПБАШ

ИЗДАТЕЛЬСТВО
«ЭРКАМ»

Аллаһ Тәгалә әйтә:

«(И, Рәсүлем!) **Без сиңа бу Коръәнне вәхи итүебез сәбәбе илә иң яхшы хикәяләү белән белдерәбез»** («Юсуф», 3)

**«Зикердән** (Тәүраттан) **соң Зәбүрдә дә яздык инде: “Ул җиргә Минем изге колларым мирасчы булачак”»** («әл-Әнбия», 105).

**«…Алар** (кяферләр) **җирдә йөреп, үзләреннән алда яшәгән кешеләрнең ахыры нинди булганын күрмәделәрме? Ахирәт йорты исә тәкъвалык ияләре өчен яхшырак. Бер дә аңламыйсызмы?»** («Юсуф», 109).

**«Без алардан әүвәл ничәмә-ничә буыннарны һәлак иткән идек! Син алардан берәрсен** (әсәрен) **таба аласыңмы? Яки аларның пышылдавын булса да ишетә аласыңмы?»** («Мәрьям», 98).

**«Алар өчен җир дә, күк тә еламады. Алар кичектерү бирелгән кешеләр дә булмадылар»** («әд-Духан», 29).

**«Әмма начар нәрсәләр эшләгән һәм соңыннан тәүбәгә килгән һәм иман китергәннәр! Һичшиксез, синең Раббың – Гафу итүче, Рәхимле»** («әл-Әгъраф», 153).

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Дин – нәсыйхәт…»* – дип әйтә (Бохари, «Иман», 42).

*«Җаным кодрәтле кулында булган Зат белән ант итәм, йә игелеккә өндәрсез, яманлыкларга чик куярсыз; яки Аллаһның өстегезгә җибәрәчәк газабын бик якында күрерсез! Ул чакта дога кылсагыз да, кабул ителмәс!..»* (Тирмизи, «Фитән», 9).

Хәзрәти Мәүләнаның Мәснәвиеннән:

«Коръәни-Кәрим – пәйгамбәрләрнең эш-гамәлләре һәм сыйфатлары ул. Коръәни-Кәримне хошуг белән укып, шуның белән яшәсәң, үзеңне пәйгамбәрләр, әүлияләр белән очрашкан дип сана! Пәйгамбәрләрнең кыйссаларын укыгач, тән читлеге җан кошына тар тоела башлар!»

Аллаһ Тәгалә әйтә:

**«Әллә кеше караучысыз калдырылган дип санаймы?»** («әл-Кыямә», 36).

**«Һичшиксез, үзләренә** (пәйгамбәрләр) **җибәрелгән кешеләрдән сораячакбыз. Һичшиксез, җибәрелгән кешеләрдән дә** (пәйгамбәрләрдән) **сораячакбыз!»** («әл-Әгъраф», 6).

**«Әгәр дә кяфер булсагыз, балаларны чал чәчле итәчәк көннән ничек котылырсыз?!»** («әл-Мүззәммил», 17).

**«Без кемгәдер озын гомер бирсәк, аның яралтылышта (яшьлеген һәм матурлыгын бозып) киресен әйләндерәбез. Әллә алар (сәфәр кайсы юнәлештә икәнен) аңламыйлармы?»** («Йәсин», 68).

**«Күк ярылгач. Йолдызлар коелгач. Диңгезләр ташыгач. Каберләр асты өскә әйләнгәч. Һәрбер җан киләчәккә ни әзерләгәнен һәм үзеннән соң** (эшли алмыйча) **калдырган һәрнәрсәне беләчәк!»** («әл-Инфитар», 1–5).

**«Алар (камил мөэминнәр) аякта торганда да, утырган килеш тә, янтыкларында килеш тә** (һәрвакыт) **Аллаһны зикер итәләр һәм күкләр белән җирнең яратылышы турында (тирән) фикерлиләр: "И, Раббыбыз! Син моны юкка яралтмадың. Син пакьсең! Безне Ут газабыннан сакла!"»** («Әли Гыймран», 191).

Хәзрәти Давыт галәйһис-сәләмнең бер мөнәҗәте:

Илаһи! Сине искә алып зикер кылучылар мәҗлесеннән мине аерма! Әгәр гафилләр мәҗлесенә китәргә теләсәм, анда юл тотканчы аякларымны сындыр! Чөнки Синең болай эшләвең минем өчен бөек рәхмәтең ул.

Мәснәвидән:

«Коръәни-Кәримнең тышкы күренешен бер микъдар кара белән язып була. Аның серләренә исә чиксез дәрьялар, ярсыз-кырыйсыз диңгезләр карага әйләнсә дә, җитмәс!

Коръәни-Кәрим – пәйгамбәрләрнең эш-гамәлләре һәм сыйфатлары ул. Коръәни-Кәримне хошуг белән укып, шуның белән яшәсәң, үзеңне пәйгамбәрләр белән очрашкан дип сана! Пәйгамбәрләрнең кыйссаларын укыгач, тән читлеге җан кошына тар тоела башлар!»

*Хәзрәти Мәүләна Җәләлетдин Руми.*

# СҮЗ БАШЫ

Үз колларын һидәяткә ирештерү өчен, аларга биргән бик күп өстен сыйфатларга өстәп, Җәнабел-Хак алар арасыннан искиткеч камил ятратылышка ия изге бәндәләрне, туры юлны күрсәтү вазифасы йөкләп, ярдәмче итеп җибәргән. Мондый изге затларның вәхи белән сөендерелгәннәре пәйгамбәрләр була. Өммәтләргә үрнәк шәхес булып торган әлеге мөбарәк илчеләргә өч вазифа йөкләнә:

1. Аллаһның аятьләрен укып, иманга чакыру;

2. Нәфесләрне тәрбияләү һәм пакьләү;

3. Китап һәм хикмәтне өйрәтү.

Раббыбызның искиткеч бер ярдәмен белдергән пәйгамбәр җибәрү гамәле, бөтен кешелекне колачлый алсын өчен, Хәзрәти Адәм белән тормышка ашырыла башлый. Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм – тәүге кеше дә, тәүге пәйгамбәр дә ул.

Әлеге мөбарәк һидәят юлы, бер-бер артлы җибәрелгән йөз егерме меңнән артык пәйгамбәр белән ныгытыла-ныгытыла килеп, асыл гакыйдәдә бер төрле булып калса да, кешелекнең шул чордагы алгарышы, цивилизация дәрәҗәсенә бәйле рәвештә яхшыра барып, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмдә камиллеккә ирешә. Кыяматкә хәтле кешеләр өчен һидәяткә юл күрсәтүче булган, могҗизалары белән кяферләрне гаҗизлектә калдырган, мөэминнәрне гаҗәпләндергән Коръәни-Кәрим Аңа һәм Аның аша бөтен кешелеккә олуг бүләк итеп җибәрелә.

Коръәни-Кәрим кешеләргә, аларны туры юлга кертеп, дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирештерү өчен юллана. Бу максатның үтәлешен тәэмин итү өчен, ул үз ният-теләген гамәлгә ашырганда, бик күп темаларга кагыла. Аерым алганда, үткәндәге өммәтләрнең кыйссаларын сөйләп бирү – Коръәннең әнә шул максатына хезмәт иткән иң билгеле үзенчәлекләреннән берсе. Коръәни-Кәримдәге кыйссалар борынгы кавемнәр кичергән гыйбрәтле вакыйгалар ярдәмендә кешеләрне туры юлдан язуның куркынычы турында кисәтә һәм Хак Тәгаләгә гыйбадәт кылуга өндәү кебек хикмәтле вазифа үти. Шул рәвешле ялгыш, тыелган мөнәсәбәтләр, гамәлләр һәм боларга җавап рәвешендә илаһи гаделлекнең чагылышы яисә дөрес гамәлләр һәм нәтиҗәдә бәхеткә илткән әҗер-саваплар анык күрсәтелә. Бу исә шуларга охшаш хаталардан тыю өчен, сабак һәм гыйбрәт бирү белән бергә, бәхеткә ирештерәчәк эш-гамәлләргә өндәү максатына да хезмәт итә.

Коръәни-Кәримнең үткәндәге өммәтләр турында кыйссалары ярдәмендә кешелекне туры юлга өндәүнең әһәмияте шуның белән дә раслана: бу кыйссалар изге Китапның өчтән берен тәшкил итәр дәрәҗәдә киң һәм тәфсилле формада тәкъдим ителгән.

Әлеге кыйссаларның мөһимлеге һәм алардан сабак алырга кирәклеге турында Хәзрәти Мәүләна Җәләлетдин Руми болай ди:

«Коръәни-Кәрим – пәйгамбәрләрнең хәл-әхвәле һәм сыйфатлары ул. Коръәни-Кәримне түбәнчелек белән укып, шуның белән яшәсәң, үзеңне пәйгамбәрләр, әүлиялар белән очрашкан дип сана! Пәйгамбәрләрнең кыйссаларын укыгач, тән читлеге җан кошына тар тоела башлар!»

«Без бу тән читлегеннән бары шушы чара ярдәмендә генә котылдык. Ул читлектән ирекkә чыгу өчен шушы ысулдан, ягъни тәүхид юлыннан барудан башка чара юк!..»

«Җилнең Гад кавемен нишләткәнен күрмәдеңме? Суның туфанда нишләгәнен ишетмәдеңме?»

«Ул ачулы диңгезнең (Кызыл диңгезнең) Фиргавенне ничек һәлак иткәнен; Карунның ничек җир астына җибәрелгәнен, Әбабил кошларының фил гаскәрен нишләткәнен, үзен тәңре дип игълан иткән Нәмрудның башын кечкенә бер чебеннең ничек ашаганын, Хәзрәти Лутның әхлаксыз кавеме өстенә ничек ташлар яудырылганын һәм аларның кап-караңгы һәм пычрак сулы күлгә күмелгәнен белмисеңме әллә?»

«Дөньядагы җансыз дип саналган нәрсәләрнең, әйтерсең, акыллы кешеләр кебек пәйгамбәрләргә ярдәм итүләре турында тәфсилләп сөйләсәм, мәснәвием шулкадәр озын һәм күләмле булачак ки, аны кырык дөя дә күтәреп бара алмас...»

Тәүхид гакыйдәсе йөрәкләрдә ныгып урнашсын өчен, кыйссаларда пәйгамбәрләрнең дингә өндәве һәм әлеге затларга каршы өммәтләре кылган гамәлләр турында сүз бара.

Кыйссаларның хикмәте турында, Коръәннең иңдерелү максатында ярашлы рәвештә, түбәндәгечә кыскача йомгак ясарга була:

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең рәсүллеген дәлилләү, барлык пәйгамбәрләрнең тәүхидкә өндәвен күрсәтү, Китапны укучыларның бик ачык гыйбрәт алуын тәэмин итү; йөрәкләрне уятып, изге затларга якынайту һәм бозык бәндәләргә иярүдән тыю; пәйгамбәрләрне тарыган борчу-мәшәкатьләр һәм алар очрашкан бозыклыклардан бәндәләрнең сабак алуы, авырлыкларга сабыр итеп нигъмәтләргә шөкер итәргә өйрәтү.

Илаһи рәхмәт чагылышы буларак, тырышлык салуым нәтиҗәсендә туган әлеге тыйнак хезмәтем, пәйгамбәрләр календареның тәүге сәхифәсеннән соң-

гысына кадәр Коръәни-Кәримдә исем-шәрифләре очраган пәйгамбәрләрне һәм аларның тормышындагы хикмәтләрне һәм гыйбрәтләрне үз эченә ала. Монда:

Үзенә фәрештәләр сәждә кылырга мәҗбүр ителгән **Адәм** галәйһиссәләм;

Күкләрдәге искиткеч нәрсәләрнең серләрен белгән **Идрис** галәйһиссәләм;

Җирне туфаны белән көферлектән пакьләгән **Нух** галәйһиссәләм;

Аллаһны кире каккан дәүләтләрне җил-давыл белән пыран-заран китергән **Һуд** галәйһиссәләм;

Азгынлык һәм акчага уйный торган отыш уен ояларын зилзиләләр белән астын-өскә әйләндергән **Салих** галәйһиссәләм;

Нәмрудның утларын үзенең буйсынучанлыгы, ихлас иманы белән гөлбакчага әйләндергән **Ибраһим** галәйһиссәләм;

Ихласлыгы, тугрылыгы, Аллаһка тәвәккәл кылуы һәм үзен Аңа багышлавы символга әверелгән, кыяматкача, хаҗ гыйбадәтен кылганда, бөтен мөэминнәргә үзләренең тормыш кыйссалары хәтергә төшерелә торган **Исмәгыйль** галәйһиссәләм;

Бәни Исраил кавеме пәйгамбәрләре нәселен дәвам иткән **Исхак** галәйһиссәләм;

Азгынлык һәм әдәпсезлек сазлыгына батып, җир астына күмелгән Содом белән Гоморра кавеменең пәйгамбәре **Лут** галәйһиссәләм;

Тәүхид байрагын көнчыгыштан көнбатышка күтәреп барган **Зөлкәрнәйн** галәйһиссәләм;

Мәхәббәт һәм хәсрәт утында көйдерелгән, сабырлык һәйкәленә әйләнгән **Ягъкуб** галәйһиссәләм;

Күпмедер вакыт коллык, соңыннан зинданда ялгызлык кичереп, туган яктан аерылу, газап, ярлылык, аз белән канәгать булу кебек сынаулардан, нәфес белән көрәштән соң Мисыр һәм күңелләр солтаны булган һәм ай яктысыннан яктырак нурга ия **Йосыф** галәйһиссәләм;

Бәндәләрнең күңелен яулаган үгет-нәсыйхәтләре белән «Хатыйбүл-әнбия» исеменә лаек булган **Шөгаеб** галәйһиссәләм;

Ахмак Фиргавенне Кызыл диңгез чоңгылларында батырган, могҗизалар иясе **Муса** галәйһиссәләм;

Муса галәйһиссәләмнең һәрвакыт һәм һәркайда ярдәмчесе булган изге туганы **Һарун** галәйһиссәләм;

Зикере белән тауларны, ташларны, кыргый хайваннарны таң калдырган **Давыт** галәйһиссәләм;

Искиткеч зур солтанлыкка йөрәген яулап алырга ирек бирмәгән **Сөләйман** галәйһиссәләм;

Йөз ел дәвам иткән үлемнән соң, кабат терелтелеп, кыяматтә кабат каберләрдән торгызылуга бер мисал булган **Гозәер** галәйһиссәләм;

Тирән уй-фикерләр һәм сабырлыкның үрнәге булган **Әйюб** галәйһиссәләм;

Бик нык дулкынлану, вәҗед (һәртөрле эчке тойгы: сөю, шатлык, кайгы, ачыну, дулкынлану) хәлендә тәүбә-истигъфар, дога һәм зикер хикмәтләренә чумып, караңгылыкларны кичкән **Юныс** галәйһиссәләм;

Үзеннән соң «Ильяска сәлам булсын!» дип искә алырлык илаһи хөрмәт һәм мәхәббәткә лаек булган **Ильяс** галәйһиссәләм;

Галәмнәргә өстен пәйгамбәр итеп күтәрелгән **Әльясаг** галәйһиссәләм;

Мул-мул илаһи рәхмәткә тиенгән пәйгамбәр **Зөлкифл** галәйһиссәләм;

Хикмәтле нәсыйхәтләре телләрдә дастанга әйләнгән, яшерен һәм ачык гыйлемнәрне белгән **Локман Хәким** галәйһиссәләм;

Мәзлүм булып, пычкы белән икегә бүлгәндә дә, «аһ», димичә, Аллаһка багышлаган җанының нык иманын саклаган пәйгамбәр **Зәкәрия** галәйһиссәләм;

Атасы кебек шәһид үлеме белән бакыйлыкка күчкән **Яхья** галәйһиссәләм;

Башкалардан аерып торган сыйфаты нәфес тәрбиясе булган, Аллаһка сыенуы һәм ихлас ялваруы ярдәмендә авыруларга шифа биргән, үлеләрне терелткән, күккә күтәрелгән **Гайсә** галәйһиссәләм.

Йомгаклап әйткәндә, бөтен пәйгамбәрләр һәм аларның өммәтләре кичергән вакыйгаларның хәзерге заман кешесенә хас рухи ихтыяҗлар һәм кайгы-борчуларны аңларга һәм яктыртырга ярдәм итәрлек хикмәтле үзенчәлекләрен ирештерергә тырыштык. Шул ук вакытта аларның, бер-бер артлы бу дөньяга килеп, сөенечле хәбәр китерүчеләр рәвешендә, бәрәкәтле һидәят очкыннары елгасыдай галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән иң югары, камил пәйгамбәрлек ноктасы, яратылыш сере, мәхлукат нуры **Хәзрәти Мөхәммәд Мостафа** салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә әзерләүдә бурычлы, җаваплы булганнарын көчебез җиткәнчә, сүзләрнең чикле мөмкинлеген файдалана алган дәрәҗәдә аңлатырга тырышлык куйдык.

«Пәйгамбәрләр тарихы» дип исемләнгән бу китабыбыз, гомум җәмәгатьнең теләк-үтенече белән, тагын да киңәйтелде һәм дәлилләр белән баетылды.

Бу уңайдан, өлеше кергән кадерле галимнәребезгә рәхмәт белдерәбез, әлеге хезмәтләренең үзләре өчен җәрия сәдакага әйләнүен Раббыбыздан сорыйм.

**Хөрмәтле укучыларыбыз!**

Бу китапны, карап чыгу эшендә, хәдис һәм чыганакларының игътибар белән тикшереп һәм дөреслеген раслап, ихлас көчен салган кардәшләребезгә рәхмәт белдерәм, бу хезмәтләренең садакаи җария сыйфатында Хак Тәгалә каршында кабул кылынуын телим. Шулай ук файдаланган әсәр-хезмәтләрнең авторларын рәхмәт һәм хәер-дога белән искә алам, Раббымнан алар өчен мәгъфирәт (ярлыкау) һәм югары дәрәҗәләр сорыйм.

Гаҗизлек һәм зәгыйфьлегебез аркасында килеп чыккан хата-ялгышлыкларыбызның кичерелүе өмете белән Раббыбызның чиксез рәхмәте һәм мәрхәмәтенә сыенабыз.

**Эшнең уңышы бары Аллаһтан гына булыр!..**

Осман Нури ТОПБАШ
01.03.2004 - Стамбул.

***Багышлау***

Иң беренче чиратта, дөньяның үзенә бүләк итеп җибәрелгән Галәм нуры – Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең, шулай ук барлык пәйгамбәрләр һәм әулияларның хөрмәтле рухларына багышлап...

# КЕРЕШ

Без, мескен колларын, иман шатлыгы һәм тынычлыгы белән бәхеткә ирештерүче Аллаһ Сөбханә вә Тәгаләгә мактау-олылау булсын!

Кешелекне зольмәттән, караңгылыктан чыгып нурга күмелүенә сәбәп булган Галәмнәрнең чиксез куанычы – Пәйгамбәребезгә сәлам-салаватларыбыз булсын!

**Коръәни-Кәрим кыйссаларының әһәмияте**

Җәнабел-Хак Үзенең Коръәни-Кәримендә әүвәлге пәйгамбәрләр һәм аларның өммәтләре турында илаһи хикмәтләрне, гыйбрәтле вакыйгаларны, дингә чакыру белән хәлләрне, адәм баласының акылы өчен җиңел аңлашыла торган ысулдагы кыйсса шәкелендә тәкъдим итә. Әлеге үзенчәлек аяти кәримәләрдә болай аңлатыла:

نَحْنُ نَقُصُّ عَلَيْكَ أَحْسَنَ الْقَصَصِ بِمَا أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ
هَذَا الْقُرْآنَ وَإِنْ كُنْتَ مِنْ قَبْلِهِ لَمِنَ الْغَافِلِينَ

«(Әй Рәсүлем!) **Без сиңа бу Коръәнне вәхи итүебез сәбәбе илә иң яхшы хикәяләү юлы белән** (үткәндәге хәлләрне) **белдерәбез»** («Юсуф», 3).

تِلْكَ مِنْ أَنْبَاءِ الْغَيْبِ نُوحِيهَا إِلَيْكَ مَا كُنْتَ تَعْلَمُهَا أَنْتَ
وَلَا قَوْمُكَ مِنْ قَبْلِ هَذَا فَاصْبِرْ إِنَّ الْعَاقِبَةَ لِلْمُتَّقِينَ

«(Рәсүлем!) **Болар – Без сиңа вәхи иткән гаиб хәбәрләрдән. Моңа кадәр алар турында син дә, кавемең дә белми иде. Шулай булгач, син дә сабыр ит. Чөнки эшнең хәерле соңы –** (сабыр итеп) **сакланганнарда»** («Һуд», 49).

وَكُلًّا نَقُصُّ عَلَيْكَ مِنْ أَنْبَاءِ الرُّسُلِ مَا نُثَبِّتُ بِهِ فُؤَادَكَ
وَجَاءَكَ فِي هَذِهِ الْحَقُّ وَمَوْعِظَةٌ وَذِكْرَى لِلْمُؤْمِنِينَ

**«Пәйгамбәрләр турындагы хәбәрләрдән һәрберен синең күңелеңне** (сабырлык белән тутыру һәм) **куәтләү өчен сөйлибез. Боларда сиңа хак мәгълүмат һәм вәгазь, кешеләр өчен исә бер үгет килде»** («Һуд», 120).

**Коръәни-Кәрим кыйссаларының максаты**

Коръәни-Кәрим кыйссалары кайбер дини максатларны тормышка ашыруны күз уңында тота. Бу максатлар киң һәм колачлы эчтәлеккә ия, чөнки аерым кыйссаларның максатлары бер үк вакытта диярлек бөтен Коръәни максатларны үз эченә ала. Мондый күзлектән караганда, кыйссалар вәхиләрнең һәм пәйгамбәрлекнең хаклыгын дәлилләү, Аллаһның барлыгын һәм берлеген исбатлау, диннәрнең асылда берлеге, вәгазьләү, шатлыклы хәбәр ирештерү, илаһи кодрәт ачык күренгән очраклар, хәерле гамәлләр белән золым-явызлык, сабыр итү, уртаклашу, шөкер итү, рәхмәтсезлек һәм башка бик күп дини вә әхлакый мәсьәләләрне, максат-моратларны колачлый, шуларны белдерү чарасы булып тора.

Коръән кыйссаларының иң әһәмиятле һәм ачык максатлары турында сөйләгәндә, түбәндәгеләрне аерып күрсәтергә мөмкин:

1. Иман нигезләрен исбатлау һәм аңлату;

2. Вәхиләрне һәм пәйгамбәрлекне исбатлау.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм укый-яза белми, гыйлем алмый. Аның яһүди һәм нәсара дине әһелләре белән утырып әңгәмә корганы да һич билгеле түгел. Шуңа карамастан, аңа Коръәндә нәсара һәм яһүдиләрне дә шаккатырган кыйссалар иңдерелә. Ул гына да түгел, кайберсендә вакыйгалар шулкадәр тирән итеп һәм нечкәлекләр белән тасвирлап бирелә, әйтик, Ибраһим, Йосыф, Муса һәм Гайсә галәйһимүс-сәләм кыйссаларындагы кебек. Боларның Коръәндә сурәтләп бирелүе аның илаһи вәхи булуына бер дәлил тәшкил итә. Коръән кайбер кыйссаларның башында яки ахырында аларның максатын аермачык белдереп куя:

وَمَا كُنْتَ بِجَانِبِ الْغَرْبِيِّ إِذْ قَضَيْنَا إِلَى مُوسَى الْأَمْرَ وَمَا كُنْتَ مِنَ الشَّاهِدِينَ.
وَلَكِنَّا أَنْشَأْنَا قُرُونًا فَتَطَاوَلَ عَلَيْهِمُ الْعُمُرُ وَمَا كُنْتَ ثَاوِيًا فِي أَهْلِ مَدْيَنَ تَتْلُو
عَلَيْهِمْ آيَاتِنَا وَلَكِنَّا كُنَّا مُرْسِلِينَ. وَمَا كُنْتَ بِجَانِبِ الطُّورِ إِذْ نَادَيْنَا وَلَكِنْ رَّحْمَةً
مِّنْ رَّبِّكَ لِتُنْذِرَ قَوْمًا مَّا أَتَاهُمْ مِّنْ نَّذِيرٍ مِّنْ قَبْلِكَ لَعَلَّهُمْ يَتَذَكَّرُونَ

**«Мусага эшне вәхи иткән чакта,** (Хәбибем) **көнбатыш ягында түгел идең һәм син ул вакыйганы күрүчеләрдән булмадың. Ләкин Без** (Мусадан соң) **бик күп нәселләр яралттык, аларга гомерләр озын килде. Безнең аятьләребезне укыганда, син Мәдйән халкы арасында булмадың һәм алардан ул аятьләрне өйрәнмәдең. Ләкин** (үткәннәр турында хәбәрләрне Сиңа Без җибәрдек. Без Мусага дәшкән чакта, син Тур янында түгел идең, ләкин синнән алда үзләренә үгетләүче (бер пәйгамбәр) **килмәгән бер кавемне**

**кисәтер өчен, Раббыңнан бер рәхмәт буларак җибәрелдең. Бәлки, алар, уйлап, үгет алырлар»** («әл-Касас», 44–46).

3. Адәм галәйһиссәләмнән Пәйгамбәребезгә хәтле диннең Аллаһтан килгәнен, барлык мөэминнәрнең бер өммәт булуын, бердәнбер Аллаһ һәркемнең Раббысы икәнлеген аңлату.

4. Аллаһның пәйгамбәрләренә һәм аерым бер колларына ирештергән нигъмәте турында сөйләү.

5. Адәм баласын мәңгелек дошманы булган шайтанга каршы вәгазьләү.

Аллаһ Тәгалә әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ كُلُوا مِمَّا فِي الْأَرْضِ حَلَالًا طَيِّبًا
وَلَا تَتَّبِعُوا خُطُوَاتِ الشَّيْطَانِ إِنَّهُ لَكُمْ عَدُوٌّ مُّبِينٌ. إِنَّمَا يَأْمُرُكُمْ بِالسُّوءِ
وَالْفَحْشَاءِ وَأَنْ تَقُولُوا عَلَى اللَّهِ مَا لَا تَعْلَمُونَ

**«И, кешеләр! Җирдә хәләл һәм пакь булганнардан ашагыз. Шайтанның эзләреннән бармагыз, чөнки ул – сезнең ап-ачык дошманыгыз. Чынлыкта, ул сезгә начар нәрсәләрне, кабахәт эшләрне һәм Аллаһка каршы үзегез белмәгән нәрсәләрне әйтүегезне әмер итә»** («әл-Бәкара», 168–169).

6. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм барлык мөэминнәргә юаныч биреп, аларның күңелләрен ныгыту, Аллаһның ахыр чиктә пәйгамбәрләренә ярдәм итеп, ялганчыларны һәлак кылачагын аңлату.

Бу исә Пәйгамбәребезгә булышу һәм Ул иманга чакырган затларның аңнарына йогынты ясау максатын күздә тота.

7. Кешенең акрынлап тәрбияләнүен, ипкә килүен тәэмин итү.

Кыйссаларның тагын башка бик күптөрле максатлары да бар. Болар арасында Аллаһның иксез-чиксез һәм тиңсез әсәрләргә кодрәтле икәнлеген аңлату һәм күрсәтеп бирү дә әһәмиятле максатлардан булып тора. Мәсәлән, Хәзрәти Адәмнең юктан бар ителүе һәм Гайсә галәйһиссәләмнең атасыз дөньяга китерелүе – шундыйлардан.

Кыскасы, Коръәни-Кәримдәге кыйссалар ярдәмендә Җәнабел-Хак адәм баласына яшерен һәм ачык рәвештәге чиксез күп нәрсә турында хәбәр бирә, өйрәтә. Шулай ук һәр пәйгамбәрдә аерым бер үзенчәлекне алгы якка чыгарып, бу хакта кешенең миенә һәм аң-гакылына мәгълүмат урнаштыра. Әйтик, түбәндәгечә:

Пәйгамбәрләр арасында Хәзрәти Нух галәйһиссәләмнең тормышына карасак, беренче чиратта иманга өндәү, түземлек, сабырлык һәм ахыр чиктә, явызлыкка һәм кяферләргә карата бик көчле нәфрәт күзгә ташлана.

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләмнең тормышы ширеккә каршы аяусыз көрәш һәм мәҗүси потпәрәстлекне бетерү юлында уза, шулай ук Нәмрудның утларын гөлбакчага әйләндергән Хак Тәгаләгә тәвәккәл кылу, үзеңне багышлау һәм ихлас бирелгәнлек мәсьәләсендә искиткеч үрнәк күрсәтә.

Хәзрәти Муса галәйһиссәләмнең тормышы залим Фиргавен һәм аның яраннары белән көрәштә уза, аннары үзе алып килгән хак-хокук нигезендә мөэминнәр өчен иҗтимагый тәртип формасын булдыра.

Хәзрәти Гайсә галәйһиссәләмнең иманга чакыру эшендәге башкалардан аерып торган сыйфаты кешеләргә карата шәфкать һәм мәрхәмәтлелек тулы йөрәккә ия булудан гыйбарәт. Аның өстен сыйфатлары арасында кешеләргә карата кече күңеллелек, йомшак мөнәсәбәт тә игътибарга лаек.

Хәзрәти Сөләйман галәйһиссәләмнең, дастаннарда җырланган күз камаштырырлык солтанлыгына, байлыгына карамастан, кече күңеллелек һәм шөкер кылу аша йөрәгенең сафлыгын, пакьлеген саклап, Аллаһка гыйбадәт кылуда зур дәрәҗәләргә ирешүе сокландыра.

Хәзрәти Әйюб галәйһиссәләмнең тормышында бәла-казалар каршындагы сабырлыгы, нинди генә халәттә дә Аллаһны мактавы һәм Аңа шөкер кылуы, искиткеч югары дәрәҗәдә була.

Хәзрәти Юныс галәйһиссәләмнең тормышы, Аллаһка юнәлеп, Аңа үзеңнең бар булмышыңны багышлауның һәм, ялгышлыгы аркасында үкенү хисе тоеп, тәүбәгә бирелгәнлекнең камил бер үрнәге булып тора.

Хәзрәти Йосыф галәйһиссәләм, әсир вакытта да, Хак Тәгаләгә бирелгәнлек һәм Аңа өндәүдә иң югары дәрәҗәгә ирешә. Байлык, шөһрәт һәм мөлкәт иясе булган чибәр хатын «әйдә, яныма кил», дип, ымсындырып чакырып торган чакта да, искиткеч гыйффәтлелек үрнәге күрсәтә. Аның диндарлык белән бизәлгән йөрәге – камил мөнәсәбәт өчен гаҗәеп бер чишмә, чыганак ролен үти.

Хәзрәти Давыт галәйһиссәләмнең тормышы илаһи бөеклек каршындагы сабак алырдай сәхифәләргә бай. Аның да, Аллаһтан куркып, елый-елый хәмедсәнәләр әйтүе, зикер кылуы, догалар белән ялварып, гыйбадәттә Аллаһка йөз тотуы бик гыйбрәтле.

Хәзрәти Ягъкубның гомере исә, дөнья караңгылыкка чумган вакытта да, өметсезлеккә бирелмичә, күркәм сабырлык белән Аллаһка тәвәккәл кылырга һәм Аның рәхмәтеннән өмет өзмәскә кирәклегенә кешеләр өчен бик зур үрнәк ул.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы исә боларның һәркайсын колачлаган бер олуглык, камиллеккә ия ки, аны сүз белән сөйләп-тасвирлап бирү мөмкин түгел.

### Коръәни-Кәрим кыйссаларының үзенчәлекләре

Коръәни-Кәрим вакыйгаларның асылына игътибар юнәлтә. Анда вакыт һәм урын кебек элементларга, аларның атамаларына, гомумән алганда, әллә ни әһәмият бирелми. Чөнки вакыйгаларның максатына хезмәт итмәгән нечкәлекләргә кереп китү мәсьәләне вак детальләр белән чуарлый һәм кыйссадан чыгачак нәтиҗәне яшереп, аны аңлап алуны авырлаштыра.

Коръән кыйссаларында күзгә ташланган тагын бер үзенчәлек түбәндәгедән гыйбарәт.

Коръәни-Кәрим, кыйссаны нинди сәбәп белән тапшыруга карап, аның бары максатка ярашлы өлешен генә карый. Кыйссаның дини максатны гына күздә тотуына гына әһәмият биргәнлектән, вакыйганы тарихи эзлеклеккә карамыйча, башыннан, уртасыннан яки ахырыннан сөйләнә. Хак Тәгалә, үзе мөрәҗәгать иткән затны (адресатны) кыйссадагы вакыйгалар эченә чумдырып арытмыйча, арага күңелләрне сафландырып җибәрәчәк дини өндәү-кисәтүләр һәм чакырулар кертеп җибәрә.

Коръән кыйссалары, гомумән алганда, адресатка багышланган бер кереш белән башлана. Андагы вакыйгалар, коры сүзләр белән генә тасвирланмыйча, җанлы, хәрәкәтле сурәтләнеп, бик анык рәвештә тәкъдим ителә. Җөмләләрдә кешенең тормыш чынбарлыгын чагылдырган әһәмиятле күренешләр ачып салына, ләкин әлеге вакыйгалар колачлаган бик күп нечкәлекләр төшереп калдырыла. Мондый вакыйгаларның барысы дә Коръәни-Кәримдә кабат-кабат искә алына.

### Кабатлауларның хикмәте

Коръән кыйссаларының иң мөһим үзенчәлекләреннән берсе – кабатлаулар. Кабатлау алымы Коръәни-Кәримдә, башка темаларга караганда, аеруча кыйссаларда күзгә ташлана. Һәр сүрәдә бер кыйсса гына искә алынмый, шул ук вакытта бер кыйсса бер үк сүрәдә кабатланмый. Кабатлау нигездә тулы тәкрарлау рәвешендә түгел, сүрәнең гомум барышында сүз уңаеннан һәр юлы ниндидер башка үзенчәлекне белдергән искә алып узу формасында башкарыла.

Әйтик, һәр аерым үзенчәлек, төрле гыйбрәтле сабак алу өчен нигез булып, яшерен галәмнәргә мең дә бер рухи тәрәзә ача. Мәсәлән, Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмгә Иблиснең сәҗдә кылмавы вакыйгасы җиде тапкыр кабатланып искә алына һәм һәркайсында Иблиснең берәр хәйлә-мәкеренә игътибар юнәлтелә.

Бу кабатлауларның хикмәтен аңлаткан аяти кәримәләрдә болай дип әйтелә:

وَكَذَلِكَ أَنْزَلْنَاهُ قُرْآنًا عَرَبِيًّا وَصَرَّفْنَا فِيهِ مِنَ الْوَعِيدِ لَعَلَّهُمْ يَتَّقُونَ أَوْ يُحْدِثُ لَهُمْ ذِكْرًا

**«**(Рәсүлем!) **Шушылай Без аны гарәпчә Коръән итеп иңдердек һәм анда янауны күп кабатладык, бәлки алар** (шуның бәрабәренә гөнаһларыннан) **сакланырлар яки** (Коръән) **аларга нәсыйхәт бирер»** («Та-һә», 113).

وَذَكِّرْ فَإِنَّ الذِّكْرَى تَنْفَعُ الْمُؤْمِنِينَ

**«Ләкин үгет бирүне дәвам ит** (хәтерләтеп тор)**, чөнки вәгазь** (искә төшерү) **иман китергән кешеләргә файда бирә»** («әз-Зарият», 55).

Кабатлаулар төп максатны төрле ысуллар белән белдерә. Шуңа күрә агымдагы мәсьәләләр кабатланмый. Мәсәлән, Хәзрәти Муса галәйһиссәләмнең тууы, яшь чагы һәм өйләнүе турында кабатлап сөйләнми. Әмма фиргавен белән очрашуы, сихерчеләр белән ярышы һәм явыз Бәни Исраил кавеменең хәле кебек, пәйгамбәрлекнең максаты күзлегеннән караганда бик тә әһәмиятле булган мәсьәләләр нәкъ дүрт урында кабатлана.

Икенче яктан караганда, бер шәхескә бәйле мәгълүматның төрле урыннарда искә алынган кисәкләре бер урында тупланганда, камил бер бөтенлекне күзәтәбез. Мондый бөтенлеккә ия кыйссалар арасында бернинди дә бәхәс һәм каршылык булмыйча, гомуми бер тема кебек тәкъдим ителә.

Сүз кыйссаларда бик күп мәгънәләрнең кабатлануы турында бара. Моның иң мөһим максаты – илаһи һәм бөек максатларның җаннарга һәм күңелләргә күнегелгән бер рәвештә искә алынуы. Чөнки кеше, үзенә тәкъдим ителгән бер мәсьәләне төрле шәкел, ысуллар һәм гыйбарәләр белән кабатлап биргәндә, тагын да яхшырак үзләштерә. Бу да кабатлауның кеше психологиясенә туры килә торган илаһи тәрбия һәм сафландыру ысулы буларак, Китабуллаһта урын алуын күрсәтә.

Бигрәк тә кабатлау, бер үк мәгънәне бер-берсеннән аерылып торган гыйбарә калыплары һәм төрле ысуллар белән ачыклап, Коръәннең Аллаһ тарафыннан иңдерелгән булуын һәм кешеләрнең шуңа охшаган бернәрсәне дә эшли алмаячакларын исбатлаган илаһи могҗизаларның берсе булып тора.

Теге яки бу кабатлау турында телгә алганда, кайвакыт тәфсилләп бирү, кайвакыт кыскача асылы кабатлана. Шулай итеп Коръәни-Кәрим төрле дәрәҗәдәге һәм төрле аң-зиһенгә ия кешеләргә мөрәҗәгать итә. Чөнки кайбер кешеләргә кыскача аңлату җитәрлек булса, башкаларына исә тәфсилләп сөйләү кирәк. Өстәвенә, Коръән гади халыктан алып аксөякләргә кадәр кешелекнең барлык катламнарына да мөрәҗәгать итә. Шуңа күрә һәр дәрәҗә, һәр

катлам һәм һәр сыйныф, үзләренең мөмкинлекләре һәм сәләтләреннән чыгып, аннан файдалана ала.

Коръәни-Кәримдәге сүзләрнең һәм җөмләләрнең кабатланулары, тагын бер искә төшерү максаты белән бергә, шаккатыру һәм аптырату, куркыту, игътибарны җәлеп итү һәм тасвирлы җанландыру кебек матур һәм төзек сөйләм ысулларының берсен куллану өчен дә кирәк. Мәсәлән, «Карига» сүрәсендә «اَلْقَارِعَةُ» сүзенең өч тапкыр кабатлануы кыямәтнең дәһшәтле манзарасын тыңлаучыга бик үтемле хис иттерү хикмәтенә нигезләнә.

Икенче яктан да карыйк. «ар-Рахман» сүрәсендә кешеләр һәм җеннәр өчен яралтылган нигъмәтләр санап кителә, шул җөмләләрдән соң:

فَبِأَيِّ آلَاءِ رَبِّكُمَا تُكَذِّبَانِ

**«Шулай булгач, Раббыгызның кайсы нигъмәтләрен инкяр итә аласыз?»** дигән җөмлә утыз бер тапкыр кабатлана. Шулай итеп колларга, ваемсызлык (гафләт) пәрдәләрен ачып җибәреп, илаһи нигъмәтләрне кабул итү һәм шөкер вазифасын искә төшерә. «ар-Рахман» сүрәсендә утыз бер тапкыр очраган бу кабатлауның туйдырмыйча һәм күңел тынычлыгы белән укылуы гарәп әдәбиятында һич тиңе булмаган гаҗәп хосусият санала.

Шулай ук «Мүрсиләт» сүрәсендә ун тапкыр кабатланган:

وَيْلٌ يَوْمَئِذٍ لِّلْمُكَذِّبِينَ

**«Ул көн ялганлаучыларның хәле аяныч»**, дигән аять, бик күп илаһи хикмәтләр тасвирланган аятьләрдән соң килеп, ялганлаучыларның хәсрәт тулы язмышы һәм куркыныч җәзага дучар булулары турында хәбәр итә. Шул сәбәпле мөфәссирләр (Коръәни-Кәримне тәфсирләүчеләр, аңлатучылар) бу аять алдыннан аңлатылган мәгънәләрне игътибар үзәгенә алып:

«Хөкем көнендә Аллаһның бөек аятьләрен һәм чиксез кодрәтен, исәпсез-хисапсыз илаһи нигъмәтләрен, газап урыны булган җәһәннәмне һәм савап урыны булган җәннәтне танымаган ялганлаучыларның хәле аяныч», – рәвешендә аңлатканнар.

Коръән – хакыйкатькә өндәүче һәм һидәяткә юл күрсәтүче, дога һәм зикер китабы. Дога һәм зикернең хикмәте һәм тәэсире кабатлый-кабатлый ачыклана. Намазларның һәр рәкәгатендә «Фатиха» сүрәсенең кабат-кабат укылуы, тәсбихнең утыз өч, туксан тугыз һәм йөз унбер кебек төрле саннарда башкарылуы, рөкугъ һәм сәҗдәләрдәге тәсбихләр барлык шушы кабатлаулардагы бәрәкәт белән аларның калебләргә яхшы ук үтеп кертелү максатына хезмәт итә. Бу төрдәге гыйбадәтләр колның Раббысы белән элемтәсен куәтләндергән кебек, күп әйтелгән салават-шәрифләр дә Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә

сәлләм белән элемтәне яхшырта. Килер бер заман, күп тапкырлар әйтелгән зикерләр йөрәк белән аңда шул зикернең хикмәтенә күчешне тәэмин итәр.

Әйтик, Җүнәйди Багдади хәзрәтләренә берсе килеп:

«Остазым, «Лә иләһә илләллаһ»ның мәгънәсе ничек?» – дип сорый. Ул болай дип җавап бирә: «Углым, бу сүзләрне күп тапкырлар кабатла, мәгънәсенең хакыйкатенә төшенерсең».

Икенче яктан, калеб һәм тел аһәңе белән башкарылган Коръән укулар һәм кабатланган Коръәни-Кәрим сүрәләре төрле тәэсирләр тудыра.

Шулай итеп, «Хәшер» сүрәсенең соңгы өч аятенең фазыйләте хакында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

*«Һәр көн иртән өч тапкыр «أَعُوذُ بِاللّٰهِ السَّمِيعِ الْعَلِيمِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ» дигәннән соң, «Хәшер» сүрәсенең ахыргы өч аятен укыса, Аллаһ аңа ахшамга кадәр ярлыкануын теләп торачак җитмеш мең фәрештәне җибәрер. Әгәр ул кеше шул көнне үлсә, шәһит буларак китәр. Кичен укыса да шулай ук».* (Тирмизи, «Фәдаилүл-Куръан», 22.)

«Вакыйга» сүрәсен укыган кешенең мохтаҗлыктан котылуы, кайбер мәгълүм аятьләрне укыганнан соң авыруларның сәламәтләнүе һәм боларга охшаган бик күп мисаллар Коръәни-Кәримдә бар. Чөнки Коръәни-Кәримнең әйтелеш һәм мәгънә ягыннан илаһи сүз булуы күзлегеннән караганда, кирәк икән укылган аятьләрнең кабатлануы, һәм кирәк икән эчтәлекнең бер үк яисә төрле сүзләр белән кабатлануыннан, мәгънәви рухи тынычлыкның барлыкка килүе һәм моның кешенең рухи көченә һәм хәтта матди ягына да илаһи ихтыяр көче кысаларында тәэсир итүе турында сүз бара. Ләкин барлык шушы чагылышларның тормышка ашуы өчен укыган кешенең күңеле билгеле бер халәткә җитүе кирәк. Мәсәлән, Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе белән бер бәдәви арасында булган хәл турында хәдистә тасвирланган күңел халәте турында никадәр күркәм итеп сөйләнә:

Беркөнне бер фәкыйрь бәдәви Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһедән сәдака сорый. Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе, шул мизгелдә башка төрле мөмкинлеге булмаганга күрә, җирдән бер уч ком ала да, нидер укып, шул комга өрә. Шуннан соң шул ком бәдәвинең учларына алтын булып коела. Бәдәви бу хәлгә хәйран кала. Моның ничек барлыкка килүен, учындагы комга ниләр укыганын сөйләтү өчен, Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһегә ялвара. Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе исә бик тыныч рәвештә укыган нәрсәнең «Фатиха» сүрәсе булуын әйтә. Моңа бик куанып, җирдән бер уч ком алган бәдәви, «Фатиха» сүрәсен укып, комга өрә. Ләкин ком һаман да ком булып кала. Бәдәви Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһедән моның хикмәтен сорый. Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе исә эшнең асылын:

«Аерма – калебләрдә», – дип нәтиҗә чыгара.

Коръәнне йә гафләт сәбәпле, яисә мөмкинлекләре булмаганлыктан тулысынча укымаган кешеләр кыска гына бер сүрәне рәхәтләнеп укый ала. Моның өчен Халикъ Тәгалә Үз сүзләренең иң әһәмиятлеләрен кайвакыт өлешчә, кайвакыт тулысынча илаһи бер тапкыр сүз буларак бөек шифрлар хәлендә кыска сүрәләргә тараткан һәм, гадәттә, һәрберсен кечкенә бер Коръән хөкемендә кылган. Бу сәбәпле Имам Шәфигый хәзрәтләре әйткән:

«Шаять, бөтен бер Коръәни-Кәрим урынына бары тик «Гаср» сүрәсе генә иңдерелгән булса да, бу да җитәр иде. Чөнки анда исламның барлык нигезләрен дә табарга мөмкин».

Төрек шагыйре Мәхмәд Акыйф түбәндәге юлларында «Гаср» сүрәсе белән бәйле бу хикмәтнераслый:

«Халикъның исәпсез исемнәре бар, иң башта:

Хак. Никадәр олы сөенеч кол өчен хакны кулыннан тоту!

Әгәр әсхабе-кирамнан аерылыйк, дисәләр,

Һичшиксез, «Вәл-Гаср » сүрәсен укыр идем, ник шулай?

Чөнки ул серле. Бөек сүрәдә коткарылу серләре;

Башта хакыйкый иман килә, аннан соң – тугрылык,

Аннан соң – хак, аннан – чыдамлык, менә, дустым, кешелеклелек.

Дүртесе бергә кушылса, борчымас сине һичнинди хәсрәт».

**Коръәни-Кәримдә пәйгамбәрләр һәм алар турында кыйссалар**

Коръән кыйссаларында пәйгамбәрләр кешелек дөньясының һәрьяклап иң үзенчәлекле шәхесләре буларак тәкъдим ителә. Болар нинди дә үзләштерелгән гайрәт белән түгел, ә илаһи карар белән сайланган.[1] Аяти кәримәләрдә әйтелә:

وَاجْتَبَيْنَاهُمْ وَهَدَيْنَاهُمْ إِلَى صِرَاطٍ مُّسْتَقِيمٍ

**«Без аларны** (бөтен пәйгамбәрләрне) **сайладык һәм аларны туры юлга ирештердек»** («әл-Әнгам», 87).

1. Пәйгамбәрлекнең үзең эшләп алып барлыкка китерелгән сыйфат, вазифа түгел, илаһи чыганаклы булуы шушы аяти кәримәләрдән дә аңлашыла:
«Бу (пәйгамбәрлек) – Аллаһның фазылы. Ул аны теләгәненә бирә» («әл-Җумуга», 4).
«Аларга бер аять килгәч, “Аллаһның пәйгамбәрләренә бирелгән нәрсәләрдәй бернәрсә безгә дә бирелми торып, ышанмаячакбыз”, – диләр. Аллаһ үзенең рисаләтен әманәт итәчәк урынны яхшырак белә» («әл-Әнгам», 124).
«Син бу китапның сиңа вәхи ителәчәгенә өметләнми идең, ләкин Раббыңнан бер рәхмәт (буларак килде)» («әл-Касас», 86).

اَللَّهُ يَصْطَفِي مِنَ الْمَلَائِكَةِ رُسُلًا وَمِنَ النَّاسِ إِنَّ اللَّهَ سَمِيعٌ بَصِيرٌ

**«Аллаһ фәрештәләрдән дә илчеләр сайлый, кешеләрдән дә. Һичшиксез, Аллаһ – Ишетүче, Күрүче»** («әл-Хаҗ», 75).

Коръәни-Кәримдә һәр пәйгамбәрнең бер-берсеннән аерылып торган төрле фазыйләтләре турында төрле аятьләрдә сөйләнә. Мондый аяти кәримәләрдән берничәсендә болай диелә:

وَاتَّخَذَ اللَّهُ إِبْرَاهِيمَ خَلِيلًا

**«Аллаһ Ибраһимны Үзенең дусты итте»** («ән-Ниса», 125).

إِنَّا وَجَدْنَاهُ صَابِرًا نِعْمَ الْعَبْدُ إِنَّهُ أَوَّابٌ. وَاذْكُرْ عِبَادَنَا إِبْرَاهِيمَ وَإِسْحَاقَ وَيَعْقُوبَ أُولِي الْأَيْدِي وَالْأَبْصَارِ. إِنَّا أَخْلَصْنَاهُم بِخَالِصَةٍ ذِكْرَى الدَّارِ. وَإِنَّهُمْ عِنْدَنَا لَمِنَ الْمُصْطَفَيْنَ الْأَخْيَارِ. وَاذْكُرْ إِسْمَاعِيلَ وَالْيَسَعَ وَذَا الْكِفْلِ وَكُلٌّ مِّنْ الْأَخْيَارِ

**«Һичшиксез, Без аны** (Әйюбне) **сабыр итүче буларак таптык. Нинди күркәм бер кол иде! Һичшиксез, ул күп тәүбә кылучы иде.** (И Мөхәммәд) **Көч һәм зирәклек ияләре булган колларыбыз Ибраһимны, Исхакны һәм Ягъкубны да искә ал. Һичшиксез, Без аларны ихласлык белән** (ахирәт) **йортын истә тотканнары өчен сайлап алдык. Һичшиксез, алар Безнең хозурыбызда сайлап алынган колларыбыздан, иң яхшылардан. Исмәгыйльне, Әльясагны һәм Зүлкифлне дә искә ал. Һәммәсе дә хәерле кешеләрдән»** («Сад», 44–48).

وَاذْكُرْ فِي الْكِتَابِ مُوسَى إِنَّهُ كَانَ مُخْلَصًا وَكَانَ رَسُولًا نَّبِيًّا. وَنَادَيْنَاهُ مِنْ جَانِبِ الطُّورِ الْأَيْمَنِ وَقَرَّبْنَاهُ نَجِيًّا. وَوَهَبْنَا لَهُ مِنْ رَّحْمَتِنَا أَخَاهُ هَارُونَ نَبِيًّا. وَاذْكُرْ فِي الْكِتَابِ إِسْمَاعِيلَ إِنَّهُ كَانَ صَادِقَ الْوَعْدِ وَكَانَ رَسُولًا نَّبِيًّا.
وَكَانَ يَأْمُرُ أَهْلَهُ بِالصَّلَاةِ وَالزَّكَاةِ وَكَانَ عِنْدَ رَبِّهِ مَرْضِيًّا. وَاذْكُرْ فِي الْكِتَابِ إِدْرِيسَ إِنَّهُ كَانَ صِدِّيقًا نَّبِيًّا. وَرَفَعْنَاهُ مَكَانًا عَلِيًّا

**«**(Рәсүлем!) **Китапта Мусаны да искә ал! Һичшиксез, ул сайланган иде. Һәм бер рәсүл һәм бер нәби иде. Без Турның бәрәкәтле бер тарафыннан аңа дәштек. Һәм Без аны сердәш итеп** (пышылдап сөйләшерлек) **якынайттык. Бер рәхмәтебез буларак, кардәше Һарунны аңа бер пәйгамбәр буларак бирдек.** (Рәсүлем!) **Китапта Исмәгыйльне дә искә ал. Һичшиксез, ул сүзенә бик тугры иде. Һәм бер рәсүл һәм бер нәби иде. Ул**

**халкына намазны һәм зәкятны әмер итә иде. Раббысы аңардан разый иде. Китапта Идрисне дә искә ал. Һичшиксез, ул һәм изге (зат) һәм бер пәйгамбәр иде. Без аны өстен бер урынга күтәрдек»** («Мәрьям», 51–57).

Дөньяны яралтучы булган Җәнабел-Хакның «Хәбибем» дип атаган Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебездә исә бөтен пәйгамбәрләрнең бер-берсеннән аерылып тора торган сыйфатлары да тупланган була. Аның турында аяти кәримәдә:

وَ مَا اَرْسَلْنَاكَ اِلَّا رَحْمَةً لِلْعَالَمِينَ

**«**(Рәсүлем!) **Без сине бары тик галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрдек»**, – диелә («әл-Әнбия», 107).[2]

Ләкин пәйгамбәрләрдәге бу сайлап алынганлык үзләренә йөкләнгән бик зур һәм авыр җаваплылыкны үз эченә ала. Шулай итеп, Җәнабел-Хак аларның да гаҗиз булуларын һәм үзләренә катгый бер илаһият тапшырылмаячагы турында әйтә:

فَلَنَسْأَلَنَّ الَّذِينَ أُرْسِلَ إِلَيْهِمْ وَلَنَسْأَلَنَّ الْمُرْسَلِينَ

**«Әлбәттә, үзләренә пәйгамбәр җибәрелгән халыкларны да, җибәрелгән пәйгамбәрләрне дә, һичшиксез, сорауга тартачакбыз!»** – диелә («әл-Әгъраф», 6).

Аяти кәримәдә аңлатылган ысул белән пәйгамбәрләрдән дә, илаһи гарантия астында булган хәлдә, аларга белгертелгән кайгырту дәрәҗәсенә күрә сорау алыначак. Бер риваятьтә әйтелгәнчә, Сөләйман галәйһиссәләм үзенә бирелгән гаять зур дөнья мөлкәте һәм сакчыллыгының хисабы сәбәпле, җәннәткә башка пәйгамбәрләргә караганда да соңрак керәчәк.[3]

Пәйгамбәрләр булмаган башка кешеләр өчен бернинди дә гарантия юк.[4] Колның өлешенә тигән төрле рухи сынауларда, үзеннән өстен булганнар-

---

2. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм – дөнья өчен дә, ахирәт өчен дә җибәрелгән рәхмәт пәйгамбәре. Дөньяда – һидәяте белән, ахирәттә – шәфәгате белән рәхмәт ул. Хәдис-шәрифләрдә тәфсилләп аңлатылганча, мәхшәрдә барлык кешеләр дә тип-тигез һәм киң урында тупланачак. Күңелләре курку белән тулып, хисап тотуны көтеп торган кешеләр берзаман берәр коткаручы эзли башлар. Үзләре элек ияргән бөек пәйгамбәрләрдән ярдәм күрмәгәч, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килеп ялварачаклар. Шулвакыт Пәйгамбәр Әфәндебез, Рахман иясенең гареше алдында сәҗдәгә китеп, Җәнабел-Хактан өммәте турында сораячак. Үзенә зур шәфәгать җаваплылыгы йөкләнгәч, башта туп-туры җәннәткә керәчәкләрне, билгеле бер вакыт аралыгыннан соң Ул, шәһадәт кәлимәләреннән башка бернинди дә яхшылыгы булмаган гөнаһкярләргә карата шәфәгать кылып, аларны җәннәткә кертәчәк (Бохари, «Рикак», 51; «Тәүхид», 36; «Тәфсирү сүрә» (17) 5; Мөслим, «Иман», 322, 326, 327).
3. Карагыз: Табәрани, «әл-Мугҗәмүл-Кәбир», XII, 94–95.
4. Шул ук вакытта, бу кагыйдәдән искәрмә буларак, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм җәннәт белән сөендергән кешеләр газаптан котылу мәсьәләсендә гарантияләнгән саналалар (Гашәрә-и Мөбәшшәрә кебек).

га карап, калебен камилләштерергә, ә матди кыенлыкларга юлыкканда исә үзеннән начаррак хәлдәге кешеләргә карап гыйбрәт алырга, шөкрана хисләре белән гомерен дәвам иттерергә тырышырга кирәк.

Мәсәлән, бер хәдис-шәрифтә:

*«Сездән берегез мал һәм яратылышы белән үзеннән өстен булган берәүне күргәндә, карашын шул мизгелдә үк үзеннән түбәнрәк булганга күчерсен»*, – диелә (Бохари, «Рикак», 30).

Хәзрәти Пәйгамбәргә кагылышлы һәм Хәзрәти Гайсә галәйһиссәләмнең шәхесендә барлык пәйгамбәрләргә дә караган сорау алуны белдергән башка аяти кәримәләр шулайрак яңгырый:

يَوْمَ يَجْمَعُ اللّٰهُ الرُّسُلَ فَيَقُولُ مَاذَا أُجِبْتُمْ قَالُواْ لاَ عِلْمَ لَنَا إِنَّكَ أَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ

**«Аллаһ пәйгамбәрләрне туплаган көнне: “Сезгә нәрсә дип җавап кайтардылар?” – дип әйтер. Алар: “Бездә бернинди белем юк. Һичшиксез, син – бөтен яшеренгәнне белүче”, – дип әйтерләр»** («әл-Маидә», 109).

وَلَوْ تَقَوَّلَ عَلَيْنَا بَعْضَ الْأَقَاوِيلِ. لَأَخَذْنَا مِنْهُ بِالْيَمِينِ.
ثُمَّ لَقَطَعْنَا مِنْهُ الْوَتِينَ. فَمَا مِنْكُمْ مِنْ أَحَدٍ عَنْهُ حَاجِزِينَ

**«Әгәр ул** (Пәйгамбәр) **Безгә карата нинди дә булса сүзләр уйлап чыгарган булса иде. Без аның уң кулын тотар идек. Шуннан соң шаһ тамырын ярыр идек** (Аны яшәтмәс идек)**. Шулвакыт сезнең арагыздан аны берәү дә коткара алмас иде»** («әл-Хакка», 44–47).

فَكَيْفَ إِذَا جِئْنَا مِنْ كُلِّ أُمَّةٍ بِشَهِيدٍ وَجِئْنَا بِكَ عَلَى هَؤُلَاءِ شَهِيدًا. يَوْمَئِذٍ يَوَدُّ الَّذِينَ
كَفَرُواْ وَعَصَوُاْ الرَّسُولَ لَوْ تُسَوَّى بِهِمُ الْأَرْضُ وَلَا يَكْتُمُونَ اللّٰهَ حَدِيثًا

**«Без һәр өммәттән бер шаһит китергәч, сине дә шуларга бер шаһит буларак китергәч, ничек булачак? Ул көнне кяфер булучылар һәм Рәсүлгә каршы төшүчеләр җир үзләре белән тигезләнсен иде, дип теләрләр. Әмма бер генә хәбәрне дә Аллаһтан яшерә алмаячаклар»** («ән-Ниса», 41–42).

Ибне Мәсгуд радыйаллаһу ганһе беркөнне Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезнең теләге белән «Ниса» сүрәсен укыганда:

**«**(Әй Рәсүл!) **Һәрбер өммәттән бер шаһит китергән һәм сине дә аларга шаһит буларак күрсәткән вакыт хәлләре ничә булачак?!»** – дигән мәгънәдәге 41 нче аятькә җиткәч, Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм (42 нче аяти кәримәдәге дәһшәтле гыйбарәләрне тыңлый алмаганлыктан): *«Хәзергә*

*җитәр!»* – дип укуны туктаткан һәм Аллаһ Тәгаләнең бөеклеге каршысында елаган (Бохари, «Фәдаилүл-Куръан», 32; Мөслим, «Мусафирин», 247).

**Коръәни-Кәримнең бөеклеге һәм Пәйгамбәребезнең фазыйләте**

Югарыдагы аяти кәримәләрдә пәйгамбәрлекнең авыр җаваплылыгы белән беррәттән Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелгән Кәләмуллаһның тулаем вәхигә нигезләнгән булуы да аңлатыла. Бөек Китап бу хакыйкатьне:

ذَلِكَ الْكِتَابُ لَا رَيْبَ فِيهِ هُدًى لِّلْمُتَّقِينَ

**«Ул –** (Аллаһтан иңдерелүе мәсьәләсендә) **үзендә бер шик тә булмаган, мөттәкыйләр өчен юл күрсәтә торган Китап»**, – дип бәян итә («әл-Бәкара», 2).

Һичшиксез, бу Китапның Аллаһ тарафыннан иңдерелгән булуы, аның илаһи бөеклегенә күрә камил рәвештә тәкъдим ителүе кирәк. Бу камиллекне тәэмин иткән хосуслардан берсе – Коръәннең искиткеч кыскалыгы. Аның асыл хосусиятләреннән тагын берсе – дөньяда һәм ахирәттә кешенең сәгадәтен тәэмин итү.

Бу соңгы илаһи Китап ахыргы Пәйгамбәр Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кыямәткә кадәр дәвам итәчәк иң бөек могҗиза буларак мәрхәмәт белән иңдерелгән. Чөнки һәр пәйгамбәргә, үз заманы өчен яраклы булган һөнәренә/ысулына карап, пәйгамбәрлек вазифасын исбатлый торган берничә могҗиза бирелә. Кеше көченнән өстен булган бу илаһи могҗизаларны күзәтеп, күңелләрендә һидәят нуры булучылар пәйгамбәрләренә:

«Син – Аллаһның илчесе!» – дип аларны таныганнар, һидәяттән мәхрүм бәдбәхетләр исә:

«Син бары тик бер сихерче генә!» – дигәннәр.

Шул рәвешле пәйгамбәрләрне кабул итүчеләр дә, кабул итмәүчеләр дә гайре табигый хәлләрне – могҗизаларны танырга мәҗбүр булганнар. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм айны икегә бүлгән вакытта, бу бөек могҗизаны бөтен Мәккә халкы карап торган, ләкин моны ничек кабул итүләренә карап, күңелләре иманга яки көферлеккә юнәлгән.

Муса галәйһиссәләм үзенә бирелгән бер могҗиза буларак, зур бер аждаһага әверелгән һәм Исраил угыллары арасында киң таралган сихер һәм сихерчелекнең абруен юк иткән. Гайсә галәйһиссәләмгә исә медицина гыйлемендә һич ирешергә мөмкин булмаган бер могҗиза – үлгәннәрне терелтү могҗизасы бирелгән. Ул бөтен медицина гыйлемен гаҗизлектә калдырган.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында исә шигырь һәм матур сөйләү сәнгате чәчәк аткан була. Указ, Зүль-Мәҗаз, Мәҗәннә кебек

ярминкәләр оештырылган. Ул җирләрдә дәвернең әдип һәм шагыйрьләре бер-берсе белән ярыша торган булган. Беренчелекне казанган әсәрләрне, атлас комачларга язып, Кәгъбәнең диварларына элеп куйганнар. Шул рәвешле Пәйгамбәр Әфәндебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә кадәр Кәгъбә диварларында җиде шигырь эленгән һәм боларны «җиде элмә» (мугаллакәти-сәбга) дип атаганнар. Ләкин Коръәни-Кәримнең могҗизави матур теле һәм хитабәте алдында күп гасырлардан бирле бер гадәт буларак дәвам иткән бу әдәбият ярминкәләре тарих төпкелендә югала. Моннан соң һичбер шагыйрь ярышта җиңгән шигырен Кәгъбәнең диварына элеп куя алмый.

Шул рәвешле иң көчле хатыйпларны да гаҗизлектә калдырган Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлек кодрәте Кыямәткә кадәр бөтен вакытларны һәм барлык урыннарны да үз эченә сыйдырганлыктан, ул үзеннән алдагы барлык пәйгамбәрләрнең дә вәкаләт, кодрәт һәм могҗизаларына ия һәм боларның барысыннан да өстен була. Шуның белән берлектә, кайберәүләргә теге яки гамәлдә даими бер үрнәк кирәк булганга күрә, эшчәнлеген күп вакытта кешеләрнең хаҗәтләренә карап башкара.

Бу урында шуны да әйтеп узарга кирәк, Дөньяның Әфәндесеннән гайре барлык пәйгамбәрләрнең хезмәтләре билгеле бер заман һәм җирлек белән чикләнгән. Моннан тыш, аларның бай мөгамәлә системасы безгә килеп җитмәгән. Хәлбуки, Хәзрәти Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлеге кыямәткә кадәр барлык чорларга һәм барлык җирлекләргә юнәлеш булып хезмәт иткәнгә күрә, Аның барлык әңгәмәләре, эш-гамәлләре, иң кыскасыннан алып иң яшерененә кадәр, ышанычлы юллар аша дәлилле хәдисләр белән безгә кадәр килеп ирешә һәм бу мирас кыямәткә кадәр саклану мөмкинлегенә лаек булды.

Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең бөтен дөньяга караган вазифасы аяти кәримәләрдә болай тасвирлана:

قُلْ يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنِّي رَسُولُ اللّهِ إِلَيْكُمْ جَمِيعًا الَّذِي لَهُ مُلْكُ السَّمَاوَاتِ
وَالأَرْضِ لا إِلَهَ إِلاَّ هُوَ يُحْيِي وَيُمِيتُ فَآمِنُواْ بِاللّهِ
وَرَسُولِهِ النَّبِيِّ الأُمِّيِّ الَّذِي يُؤْمِنُ بِاللّهِ وَكَلِمَاتِهِ وَاتَّبِعُوهُ لَعَلَّكُمْ تَهْتَدُونَ

**«Әйт: “И, кешеләр! Һичшиксез, мин сезнең һәммәгезгә Аллаһның илчесемен. Күкләрнең һәм җирнең хакимлеге Аныкы гына, Аннан башка илаһ юк, Ул терелтә һәм җаннарны ала. Аллаһка да, Аллаһка һәм сүзләренә ышанган өмми пәйгамбәр булган Рәсүленә дә иман китерегез. Аңа иярегез, бәлки, һидәят таба алырсыз”»** («әл-Әгъраф», 158).

وَمَا أَرْسَلْنَاكَ إِلَّا كَافَّةً لِّلنَّاسِ بَشِيرًا وَنَذِيرًا وَلَكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ

**«Без сине бөтен кешеләргә сөендерүче һәм кисәтүче итеп җибәрдек. Ләкин кешеләрнең күбесе белми»** («Сәбә», 28).

تَبَارَكَ الَّذِي نَزَّلَ الْفُرْقَانَ عَلَى عَبْدِهِ لِيَكُونَ لِلْعَالَمِينَ نَذِيرًا.
اَلَّذِي لَهُ مُلْكُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَلَمْ يَتَّخِذْ وَلَدًا وَلَمْ يَكُن
لَّهُ شَرِيكٌ فِي الْمُلْكِ وَخَلَقَ كُلَّ شَيْءٍ فَقَدَّرَهُ تَقْدِيرًا

**«Бөтен галәмнәр өчен бер үгетләүче булсын, дип, Фурканны колына иңдергән Зат – Бөек. Күкләрнең һәм җирнең милке – Аныкы гына, Ул Үзенә бала алмады, Ул хакимлекне беркем белән дә уртаклашмады, Ул һәрнәрсәне яралтты һәм аны бер үлчәү белән тәкъдир итте»** («әл-Фуркан», 1–2).

Моның сәбәбе аңа билгеләнгән «ахырзаман»ның барлык кешеләренә Аның бер «үсвәи-хасәнә», ягъни камил бер үрнәк булуын тәэмин итү юнәлешендәге илаһи максатны үтәвеннән гыйбарәт.

Бу илаһи максатны чагылдыру өчен, Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезгә берничә могҗиза иңдерелде. Могҗизаларның максаты – халыкны тәэсирләндереп, кешеләрнең пәйгамбәргә итагатен тәэмин итү. Җәмгыятьнең иң көчле һәм абруйлы кешеләренең дә итагатен тәэмин итү максаты белән Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм, барлык башка могҗизаларына өстәп, болардан тагын да өстенрәк могҗиза – кыскалыкта камиллеккә ирешкән Коръәни-Кәрим могҗизасына нигезләнә. Могҗиза пәйгамбәрләрдән башланган гаҗәеп хәлләр булганда, аларның гавамнарны яулап алу хосусындагы тәэсире көчәюенә игътибар итеп, Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең тәблигъ эшендә бердәнбер чараны тәшкил иткән Коръәни-Кәрим тиңдәшсез могҗиза була. Бу сәбәпле, илаһи чыганак булган, әмма мәңгелек бер яктырткыч кебек Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кулы белән кешелек дөньясына тәкъдим ителгән Коръәни-Кәрим могҗизасы андагы матур һәм мәгънәле сөйләмне аңлаган «бәхетле гасыр» кешесенең Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә итагатен тәэмин иткән асыл факторга әйләнә. Шулай итеп, Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе мәңгелек сәгадәт кояшын сүндергән кебек, максатларның иң начары белән юлга чыкканда, очраклы рәвештә тыңлаган Коръәни-Кәрим аятьләре, аны бер котыптан икенчесенә күчереп, яшен тизлеге белән һидаяткә ирештергән.

Мәшһүр шагыйрь һәм әдип Имру әл-Кайсның кыз туганының Коръәни-Кәримнән кыска бер текст тыңлагач, гаҗәпләнеп һәм куркуга калып:

«Бу бернинди дә кеше сүзе булмас! Дөньяда мондый сүз бар икән, кардәшемнең шигыре Кәгъбәнең диварыннан алынырга тиеш! Барыгыз, төшерегез

шул шигырьләрне, бу аятьләрне шунда урнаштырыгыз!..» – дияргә мәҗбүр була. Бу – илаһи Китап тәэсиренә типик һәм тарихи мисаллардан бары берсе генә әле (Карагыз: Әхмәд Җәүдәт Паша, «Кысас-и-Әнбия», I, 83).[5]

Коръән-Кәримнең шундый бөеклеге сәбәпле, мөшрикләр дә ул укылган вакытта бик тәэсирләнә торган була, хәтта эчләреннән иман китерергә дә теләкләре туа. Тик бу хисләрне йөгәнләү өчен, тавыш чыгарып, тыңларга ирек бирмәскә тырышалар. Бу турыда бер аяти кәримәдә болай диелә:

وَقَالَ الَّذِينَ كَفَرُوا لَا تَسْمَعُوا لِهَذَا الْقُرْآنِ وَالْغَوْا فِيهِ لَعَلَّكُمْ تَغْلِبُونَ

**«Ул кяферләр: “Тыңламагыз шул Коръәнне, укылган вакытта тавыш чыгарыгыз. Шаять, өстен чыгарсыз”, – диделәр»** («Фуссыйләт», 26).

Ләкин кайбер мөшрикләр барыбер Коръәнне яшеренә-яшеренә тыңлый. Хәтта Әбү Җаһил кебек көчле мөшрикләр дә аны дивар артыннан яшеренеп тыңлый, инанмасалар да, тәэсиренә биреләләр. Әмма көферлекләренең нык булуы сәбәпле, бер-берсен Коръән тыңлаганда күрсәләр, качалар.

Чөнки Коръән – нигез салучы, күңелләрнең түренә үк үтеп кереп, тормыш һәм кеше хакындагы карашларны үзгәртеп, инкяр һәм көферлек караңгылыгындагы кешелек дөньясын төзәтә, кешелекклелекнең иң бөек инкыйлабын кабызып җибәрә. Җаһилият җәмгыятенең һидәят юлына басуы – моның иң ачык мисалы.

Коръән – бөек сүз ул, хәтта хайваннар да аннан тәэсирләнгән.

Мәсәлән, Үсәйд бин Худайр радыйаллаһу ганһе әйткән:

«Бер төнне “Бәкара” сүрәсен укый идем. Атым минем янымда бәйдә килеш тора иде. Берзаман ат сикергәли башлады. Укудан тукталдым, ат та тынычланды. Яңадан укый башладым, ат тагын сикергәләргә тотынды. Хәтта улым Яхъяны, ат тешли күрмәсен, дип, борчылып, яныма алдым.

Шулчак күккә карасам, өстемдә кәндилләргә охшаган нәрсәләр күрдем. Бераздан алар күккә – югарыга күтәрелеп, күздән югалдылар.

Иртән Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә бу хәлләрне сөйләгәч:

*“Укы, әй, Үсәйд, укы!”* – диде. Һәм соңрак: *“Әй Үсәйд! Ул күргәннәреңнең нәрсә икәнен беләсеңме?”* – дип сорады.

“Юк”, – дидем.

5. Сүз аның иясен хәтергә төшерә. Һәм сөйләүченең шан һәм кодрәтенә күрә, бер бөеклек һәм камиллеккә ия булыр. Шуның белән Коръәни-Кәримнең искиткеч матур һәм иркен сөйләм теле, аның иясе булган Җәнабел-Хакның кодрәте һәм бөеклегенә күрә, бөтен кешелекклелекне, шул исәптән хәтта мөнкирләрне дә, гаҗиз һәм хәйран калдырган. Бигрәк тә Коръәни-Кәримнең гайре табигый ачыклыгы, гадилеге аерым бер илаһи сер тәшкил итә, һәркем аның Иясе тарафыннан никадәр кулай бәян ителгән булуын таный, ләкин моңа охшашны тудырырга һичкем сәләтле түгел.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*“Алар синең Корьән укыганыңны тыңларга килгән фәрештәләр иде. Әгәр син укуыңны дәвам иттергән булсаң, иртәнгә кадәр сине тыңлаган булырлар иде. Ул фәрештәләр кешеләрдән яшеренмәс иде, кешеләр дә аларны күрә алыр иде”*, – диде» (Бохари, «Фәдаилүл-Куръан», 15).

Коръәни-Кәримнең барлык җан ияләрен дә тәэсирләндергән һәм яулап алган хикмәте – пәйгамбәрлек бoҗрасының соңгы буын – Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән тәмамлануы һәм моннан соңгы барлык чорлар һәм җирлекләр Аныкы булуы белән Рәсүлүллаһка җибәрелгән вәхинең камил тезмәсен тәшкил итүдән гыйбарәт. Ягъни бу соңгы илаһи Китапның дөнья беткәнчегә кадәр дәвам итәчәк һәр ихтыяҗ һәм мәсьәләгә җавап бирерлек хөкемнәрне колачлавына бәйле. Асылда, Коръәни-Кәримнең мәгънә һәм эчтәлеге ягыннан тиңдәшсез могҗизалар һәм хикмәтләр тезмәсе булуы әнә шул сыйфатына нгезләнгән.

Бу илаһи бүләк – һидәят белешмәлеге һәм пәйгамбәрлекнең дөреслеген исбатлый торган сәнгать могҗизасы буларак кыямәткә кадәр дәвам итәчәк.

Коръәни-Кәрим стилендәге матур һәм иркен сөйләм, үз эченә сыйдырган хөкемнәрнең шедевры янында мәгънә һәм эчтәлеге ягыннан барлык чорлар һәм җирлекләргә мөрәҗәгать итүе белән дә һичбер пәйгамбәргә насыйп булмаган бер китап ул. Бу өстенлекләр – аның кыямәткә кадәр дәвам итәчәгенең һәм Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дә иң күп санлы өммәткә ия булачагының иң ачык билгесе.

Коръәни-Кәримдә һәрнәрсә – гыйбарә, стиль, мәгънә, могҗиза, тарих һәм башкалар – барысы бергә Аллаһныкы. Шулай булгач, аятьләрнең төзелеш тәртибе дә вәхигә нигезләнгән һәм Пәйгамбәр Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең моңа хәтта иң кечкенә катнашы да булмаган.

Коръәни-Кәримнең стиле генә түгел, яңгыраш аһәңе дә – Аллаһтан. Коръәннең шигыренә иң кечкенә бер өстәмә, пауза яки теләсә нинди үзгәреш кертү аһәңне шунда ук боза. Узган гасырның алдынгы ислам галимнәреннән мөхтәрәм Мөхәммәд Хәмидуллаһ Коръәннең аһәңе турында шундый бер истәлек сөйли:

«Мөселман булган бер француз музыканты бер очрашуыбызда миңа “Наср” сүрәсенең кыйраәтенә мөнәсәбәтле рәвештә:

« وَرَاَيْتَ النَّاسَ يَدْخُلُونَ فِي دِينِ اللّٰهِ اَفْوَاجًا ﴿٢﴾ فَسَبِّحْ »

– дип ике аять арасында тукталып укуның музыка күзлегеннән хуш булмавын белдерде. Аңа “اَفْوَاجًا” сүзе уртасында тукталырга ярамаганны, кире-

сенчә, дәвам итеп, “فَسَبِّحْ” сүзенә күчәргә кирәклекне аңлаттым. Бу музыкант кардәшебез бөтенләй гаҗәпләнде һәм аптырашта калды һәм:

“Чыннан да шулаймы?! Синең кебек укысаң, бөтенләй башкача яңгырый. Инде хәзер иманымны пакьләргә тиешмен. Аллаһ мине ярлыкасын!..” – диде».[6]

Коръәни-Кәрим бу үзенчәлеге белән кешеләрнең күңелләрендә гадәттән тыш көчле тәэсирләр уята. Гарәпләр аны Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бәхетле авызыннан тыңлап, төркем-төркем иманга килгәннәр.

Коръәни-Кәримнең могҗизалыгына күптән түгел булган бер вакыйганы мисал итеп китерергә мөмкин.

Истанбул шәһәрендә Йералты мәчетенең имам-хатыйбы Али Үскүдарлы Хуҗа берара Габделхәмид хан заманында сарай имамы да булып тора. Аның Югары Ислам институты шәкертләре Мәхмәт Али Сары һәм Исмаил Карачам Хуҗаларның тапшыруынча, Али Үскүдарлы Хуҗа венгр короле тарафыннан бер делегация белән Венгриягә чакырыла. Төрле мәдәни чараларга катнашканнан соң, шәхсән король тарафыннан сарайга чакырыла һәм, берничә тапкыр очрашкач, Али Үскүдарлы Хуҗадан Коръәни-Кәрим укуын сорыйлар. Ул Коръәннән бер өзек укый. Мәхмәт Али Хуҗаның сөйләвенчә, бу өзек Нихавәнт мәкамендә укыла. Али Үскүдарлы ул вакытта бик яшь хафиз була, Коръән укучы, тавышы бик матур, башкаруы да бик хуш. Нәтиҗәдә, аның укыган бу илаһи сүзләре корольне шулкадәр тәэсирләндерә, ул королева янына китеп, аңа нидер сөйли. Бу вакытта Коръәни-Кәримне уку турында ниләр сөйләнгәне белән кызыксынып, Али Үскүдарлы Хуҗа тәрҗемәчедән:

«Король хәзрәтләре королевага ни дип әйтте?» – дип сорый. Ул король хәзрәтләренең королевага:

«Бу укылган сүзләр кеше сүзе булырга мөмкин түгел. Кеше язган сүзләр кешене бу кадәр тәэсирләндермәс...» – дигәнен әйтә.

Шулкадәр тәэсир итү һәм яулап алу көченә ия, акыл һәм олуглык ягыннан могҗиза булган Коръәни-Кәрим иңдерелү сәбәпле, Мөхәммәд өммәтенең башка өммәтләргә караганда күбрәк санлы булачагын Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм түбәндәгечә аңлаткан:

*«Җибәрелгән һәр пәйгамбәргә кешеләрнең иманга килүләренә сәбәп булачак бер могҗиза, һичшиксез, бирелгән. Миңа бирелгәне исә Аллаһ иңдергән Коръәни-Кәрим булды. Шуңа күрә кыямәт көнне өммәтемнең башка өммәтләрдән сан ягыннан күбрәк булуын өмет итәм»* (Бохари, «Игътисам», 1).[7]

6. Бу хәл турында җентекләбрәк укыр өчен карагыз: Мөхәммәд Хәмидуллаһ, «Куръани-Кәрим тарихи», Истанбул, 1993, 94–95 б.
7. Америкада нәшер ителгән «The World Almanac Books» басмасының 1996 елгы статистик мәгълү-

Хәдис-шәрифтә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтенең күп санлы булуына өметләнүен Коръәни-Кәрим могҗизасына бәйли. Моның шундый хикмәтләре бар:

Коръәни-Кәрим билгеле бер вакытта булып узган фактик могҗизалардан аерыла. Сүз һәм мәгънә җәһәтеннән могҗиза булып, ул кешенең акылына мөрәҗәгать итә. Акыл һәм гыйлем беткәнчегә кадәр, Коръән аятьләренә фикер ителеп төшенелер, үз эченә сыйдырган нечкәлекләр көннән-көн ачыла гына барачак.

Коръәни-Кәримнең үз эченә сыйдырган мәгънәләр аерым бер чор һәм милләт өчен генә билгеләнеп калмаячак, барлык заманнар һәм барлык кешеләрне дә сыйдырыр. Һәр гасырда бу җәһәттән аның могҗизалылыгын кабул иткән гыйлем ияләре барлыкка киләчәк, шул сәбәпле Аллаһ Рәсүленең өммәте, арта барып, дәвам итәр.

Шулай итеп, ничә гасырлар дәвамында ясалган гыйльми ачышлар Коръәни-Кәримнең могҗизалылыгын кабат-кабат игътибар үзәгенә ала һәм аның илаһи сүзләр булуын раслый. Кешенең яратылыш фазалары, галәм серләре, дөнья, кояш һәм айның торышы һәм тагын күп кенә физик, географик, тыйбби (медицинага кагылышлы), иҗтимагый һәм башка шундый өлкәләрдә ясалган тикшеренүләр һәр үткән көн саен бу хакыйкатьләрне дәлилли бара.

Мисал китерергә кирәк булса, соңгы вакытларда гыйлем дөньясында бәхәс тудырган һәм мөмкин кадәр артык гыйльми буларак та кабул ителгән нурланыш юлы белән әйберләрне күчерү турында хезмәтләр дәвам иттерелә. 2001 елда беренче тапкыр бер микъдар су, молекулаларга таркатылып, нурланыш юлы белән бер башка урынга күчерелә. Бу гыйльми чынлыкны унбиш гасыр элек, хәтта мондый нәрсәләр турында хыяллану да һич мөмкин булмаган чорда, Коръәни-Кәримдә ачык итеп белдерелә. «Нәмел» сүрәсенең 40 нчы аятендә Бәлкыйс тәхетенең ике мең километрлык ераклыктан күз ачып йомган мизгелдән дә тизрәк китерелеп җиткерелүе турында әйтелә.

Бу уңайдан Хәзрәти Мәүләна Җәләлетдин Руминың Коръәни-Кәрим хакында әйткән сүзләре вакыт узган саен тагын да яхшырак аңлашыла:

«Коръәни-Кәримнең ачык нәрсәләрен бер укка сыйган язу карасы белән язарга мөмкин. Үз эченә сыйдырган барлык серләрне белдерергә исә,чиксез дәрьялар – язу карасы, ә җир йөзендәге барлык агачлар каләм булса да, җитмәс».

Җәнабел-Хак Коръәни-Кәримгә охшаш берәр нәрсәне барлыкка китерә алмаячаклары турында кыяматкә кадәр киләчәк булган барлык кешеләр һәм җеннәр галәменә хәбәр ясаган. Коръән сүрәләренә охшаш әсәрләрне иҗат итү

матларына караганда, бөтен дөньяда, христиан һәм яһүди динендәге халыклар белән чагыштырганда, мөселманнарның саны даими арта баруы күзәтелә.

мәсьәләсендәге бу илаһи өндәү шул көннән бирле җавапсыз кала бирә. Бер аяти кәримәдә бу хакыйкать шул рәвешле белдерелә:

قُلْ لَّئِنِ اجْتَمَعَتِ الْإِنْسُ وَالْجِنُّ عَلَى أَنْ يَأْتُواْ بِمِثْلِ
هَذَا الْقُرْآنِ لَا يَأْتُونَ بِمِثْلِهِ وَلَوْ كَانَ بَعْضُهُمْ لِبَعْضٍ ظَهِيرًا

**«Әйт: “Әгәр бөтен кешеләр белән җеннәр бу Коръәнгә охшаш нәрсә булдырыр өчен җыелсалар да, хәтта берәүләре икенчеләренә ярдәм күрсәтсәләр дә, барыбер аңа охшаш нәрсә булдыра алмаслар!”»** («әл-Исра», 88).

Җәнабел-Хакның бу өндәү-чакыруын ун сүрә белән генә чикләсә дә, кешеләр аңа охшаш берәр нәрсә барлыкка китерүләреннән гаҗиз калды. Бу хакта аяти кәримәдә әйтелә:

أَمْ يَقُولُونَ افْتَرَاهُ قُلْ فَأْتُواْ بِعَشْرِ سُوَرٍ مِّثْلِهِ مُفْتَرَيَاتٍ
وَادْعُواْ مَنِ اسْتَطَعْتُم مِّنْ دُونِ اللَّهِ إِنْ كُنْتُمْ صَادِقِينَ

**«Әллә алар: “Аны** (Коръәнне) **үзе уйлап чыгарды”, – дип әйтәләрме? Әйт: “Аллаһтан башка көчегез җиткән кемсәләрне чакырыгыз да, аның кебек була алырлык ун сүрә китерегез. Әгәр тугры кешеләр булсагыз”»** («Һуд», 13).

Аллаһ Тәгалә Коръәндә өндәүнең чикләрен ниһаять бер сүрәгә кадәр киметә, бу мәсьәләдә кешеләрнең көчсезлеге һәм Коръәннең илаһи сүзләр булуының чынлыгы ап-ачык аңлашыла. Бу турыда аяти кәримәдә әйтелә:

وَإِنْ كُنْتُمْ فِي رَيْبٍ مِّمَّا نَزَّلْنَا عَلَى عَبْدِنَا فَأْتُواْ بِسُورَةٍ مِّنْ مِّثْلِهِ
وَادْعُواْ شُهَدَاءَكُمْ مِّنْ دُونِ اللَّهِ إِنْ كُنْتُمْ صَادِقِينَ. فَإِنْ لَّمْ تَفْعَلُواْ وَلَنْ
تَفْعَلُواْ فَاتَّقُواْ النَّارَ الَّتِي وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ أُعِدَّتْ لِلْكَافِرِينَ

**«Әгәр дә колыбызга индергән нәрсәдән шикләнсәгез, сез дә аңа охшаш берәр сүрә китерегез һәм Аллаһтан башка шаһитларыгызны чакырыгыз, әгәр тугры кешеләр булсагыз! Әгәр инде башкара алмасагыз, – ә сез беркайчан да башкара алмаячаксыз,[8] – кяферләргә әзерләнгән, ягулыгы кешеләр һәм ташлар булган уттан куркыгыз»** («әл-Бәкара», 23–24).

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ Коръәни-Кәримнең саф һәм ачык калеб белән укылырга тиешлеге, бары тик шулвакытта гына хикмәт, гыйбрәт һәм

8. Коръәни-Кәримне барлыкка китереп булмаган кебек, аңа зарар да китерергә мөмкин түгел. Ягъни алдагы илаһи китаплардагы ялганлау һәм бозуларның Коръәнгә кагылышы юк. Чөнки Коръәни-Кәрим: «Һичшиксез, Коръәнне Без иңдердек һәм аны Без саклаячакбыз», – дигән илаһи сүзләре белән тотрыклы булып калачагын илаһи саклавы астында булуын аңлата («әл-Хиҗер», 9).

серләрнең күңелләрне рухи тынычлыкка ирештерәчәге турында никадәр матур итеп белдергән:

«Коръәни-Кәримнең аятьләрен, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдис-шәрифләрен укыганчы үзеңә хисап яса! Гөл бакчаларындагы гүзәл хуш исләрне тоймасаң, гаепне бакчадан түгел, күңелеңнән һәм борыныңнан эзлә!..»

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү аяти кәримәдә:

أَفَلَا يَتَدَبَّرُونَ الْقُرْآنَ أَمْ عَلَى قُلُوبٍ أَقْفَالُهَا

**«Алар Коръән турында һич уйламыйлармы? Әллә йөрәкләрендә йозаклар бармы?»** – ди («Мөхәммәд», 24).

Аяти кәримәнең эчтәлегенә күрә, Коръәни-Кәримне аңлау, фикерләү, хисләрең белән тоя алу һәм серләргә төшенә алу өчен, сәламәт калебле булу кирәк. Чөнки Коръәни-Кәрим үз серләрен сәламәт калебкә генә ача. Җәнабел-Хак Коръәни-Кәримдә:

نَزَلَ بِهِ الرُّوحُ الْأَمِينُ. عَلَى قَلْبِكَ لِتَكُونَ مِنَ الْمُنذِرِينَ

**«**(И, Рәсүлем!) **Аны** (Коръәнне) **Рух әл-Әмин** (Җәбраил) **Син инзар**[9] **итүчеләрдән булырсың, дип, Синең күңелеңә иңдерде»**, – ди («әш-Шугара», 193–194).

Шуңа күрә Коръәни-Кәримне Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күңел халәте белән, сәхабәи-кирам хәзрәтләренә охшатып укырга тиешле. Аннан чынлап файдалану бу мәсьәләгә карата хөрмәт дәрәҗәсенә бәйле. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә:

*«Аллаһның минем аша җибәргән һидәят һәм гыйлем өстенә мул яңгырлар яуган бер басуга охшый. Бу басуның бер өлеше – суны сеңдергән һәм соңыннан үзендә мул ямь-яшел үләннәр үстергән уңдырышлы туфрак. Башка бер өлеше исә Аллаһның коллары файдалансын өчен суны туплап тотып, кешеләргә һәм хайваннарга эчү, үсемлекләрне сугару һәм үстереп, уруны тәэмин итә. Болардан тыш калган тагын бер өлеше исә – су саклауга да, үсемлекләр үстерүгә дә ярамаган уңдырышсыз җирләр»* (Бохари, «Гыйлем», 20).

«Бу өч төрле үзенчәлектәге җир кишәрлекләреннән беренче икесе Аллаһның, Аның Рәсүле арадашчылыгы белән җибәргәненнән файдаланып, диндә белгеч булган һәм белгәнен кешеләргә өйрәткән кешегә охшар. Өченчесе исә тирә-ягында үсеп утырган һичбер нәрсәгә күзе төшмәгән һәм Аллаһ Рәсүленең үзе белән җибәрелгән һидәятне кабул итмәгән кешегә охшар».[10]

9. Инзар – мәңгелек галәмдәге ләззәт нәтиҗәләренең җитдилеге белән куркытып, әмер итү, тыю һәм кисәтү.
10. Карагыз: Сүһрәвәрди, Гавариф, 5–6 б.

Галимнәрнең калеб мәйданы, илаһи гыйлем һәм һидәятләрнең яшәеш тулы сулары белән яшәреп, бәрәкәтле уңыш җимешләре бирде. Аллаһ Тәгалә болай ди:

أَنْزَلَ مِنَ السَّمَاءِ مَاءً فَسَالَتْ أَوْدِيَةٌ بِقَدَرِهَا

**«Ул күктән су иңдерә, шул сәбәпле үзәнлекләр сыйдырган кадәр тулалар»** («әр-Рәгъд», 17).

Ибне Габбас бу аять хакында шуны аңлатты:

«Аятьтә әйтелгән су – гыйлем, агымнар исә калебләр дигән сүз».[11]

Коръәни-Кәримнең иң бөек мөфәссире Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм булганга күрә, барлык хәдис-шәрифләр Коръәни-Кәримнең тәфсиренә нигезләнә.

Бер аяти кәримәдә Җәнабел-Хак болай ди:

وَمَا أَرْسَلْنَا مِنْ قَبْلِكَ إِلَّا رِجَالًا نُوحِي إِلَيْهِمْ فَاسْأَلُواْ أَهْلَ الذِّكْرِ إِنْ كُنْتُمْ لَا تَعْلَمُونَ.
بِالْبَيِّنَاتِ وَالزُّبُرِ وَأَنْزَلْنَا إِلَيْكَ الذِّكْرَ لِتُبَيِّنَ لِلنَّاسِ مَا نُزِّلَ إِلَيْهِمْ وَلَعَلَّهُمْ يَتَفَكَّرُونَ

**«Без синнән алда да ирләр җибәргән идек, шуларга вәхи иттек. Әгәр сез белмәсәгез, зикер ияләреннән сорагыз. Ап-ачык могҗизалар һәм китаплар белән** (җибәрелделәр)**. Кешеләргә иңдерелгән нәрсәне аларга аңлатуың өчен сиңа да бу зикерне** (Коръәнне) **иңдердек. Бәлки, алар уйланырлар»** («ән-Нәхел», 43–44).

Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң килүчеләр арасында иң бөек мөфәссирләр – гыйлеме белән гамәл кылып, Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезнең рухи тормышыннан өлеш алган әүлиялар.[12]

Гөнаһ һәм дөньяви мәшәкатьләр белән капланган һәм каралган калебләр Коръәни-Кәримнән һични ала алмаячак. Мәсәлән, көнчыгышны өйрәнүче галимнәр өчен ул уйлап чыгарган гыйлем булып, алар аны йөрәк белән кабул итмәгәнгә күрә, укыган Коръән аларга һидәят бирмәс һәм серләрен ачмас. Аллаһ Тәгалә әйтә:

---

11. Сүһрәвәрди, «Гавариф», 8 б.
12. Бу мәсьәлә белән бәйле буларак, ислам галимнәреннән мәшһүр мөхәддис һәм мөфәссир Суюти әйткән:
«Бер кеше түбәндәге гыйлемнәрне өйрәнмичә, Коръәнне тәфсир итәргә керешергә тиеш түгел. Болар – лексика, синтаксис, морфология, сүз ясалышы, мәгънәләр, аңлату, матур сөйләм, уку, язу, фикһ һәм аның ысуллары, иңдерелү сәбәпләре һәм кыйссалар, гамәлдән чыгару, кыска һәм аңлаешсыз аятьләрне ачыклаган хәдисләр һәм илаһи бүләк гыйлеме. Бу соңгы гыйлем – гыйлем белән гамәл итүче кешегә Аллаһ тарафыннан бирелгән гыйлем. “Гыйлем белән гамәл итүчегә Аллаһ белмәгәнен өйрәтер”, дигән хәдис моңа ишарәли» (Суюти, «әл-Иткан», IV, 213–215).

سَأَصْرِفُ عَنْ آيَاتِيَ الَّذِينَ يَتَكَبَّرُونَ فِي الْأَرْضِ بِغَيْرِ الْحَقِّ وَإِنْ يَرَوْا كُلَّ آيَةٍ لَّا يُؤْمِنُوا بِهَا وَإِنْ يَرَوْا سَبِيلَ الرُّشْدِ لَا يَتَّخِذُوهُ سَبِيلًا وَإِنْ يَرَوْا سَبِيلَ الْغَيِّ يَتَّخِذُوهُ سَبِيلًا ذَلِكَ بِأَنَّهُمْ كَذَّبُوا بِآيَاتِنَا وَكَانُوا عَنْهَا غَافِلِينَ

**«Мин хаксыз рәвештә җирдә тәкәбберләнгәннәрне аятьләремнән борачакмын. Шуңа күрә алар берәр могҗиза күрсәләр дә, аңа ышанмаслар, һидәят юлын күрсәләр, аны үз юллары итмәсләр. Әмма адашу юлын күрсәләр, аны юллары итәрләр. Бу аларның Безнең аятьләребезне ялган санаганнары һәм алардан гафил кешеләр булганлыклары өчен»** («әл-Әгъраф», 146).

Шуңа күрә, кайбер аяти кәримәләрдә залимнәр, кяферләр һәм фасыйклар өчен «لاَ يَهْدِى»[13], диелә.

Киң эчтәлектәге берничә кыйссаны заманыбыз өчен бер гыйбрәт, туры юлга кертү һәм игътибарны җәлеп итү мәсьәләсендә кулланган Коръәни-Кәрим – шундый олуг бер китап ул.

Раббыбыз Коръәни-Кәримдәге пәйгамбәрләрнең гыйбрәт һәм серләр тулы тормышларын чагылдыру белән, сабырлык, шөкер итү, тәвәккәллек, буйсыну, мәрхәмәт, шәфкать, тыйнаклык һәм ярдәм итүчәнлектән өлеш алып, безгә хакыйкый кол булып яшәргә насыйп итсен!..

Амин!..

13. لاَ يَهْدِى: Аллаһ һидәят бирмәс. Бу гыйбарә Коръәни-Кәримдә нәкъ 26 аятьтә очрый. Әйтик, түбәндәге аятьләр моңа мисал булып тора.

وَاللَّهُ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الظَّالِمِينَ **«Аллаһ залимнәр кавемен һидәят итми»** («әл-Бәкара», 258);

وَاللَّهُ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الْكَافِرِينَ **«Аллаһ кяферләр кавемен һидәят итми»** («әл-Бәкара», 264);

وَاللَّهُ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الْفَاسِقِينَ **«Аллаһ исә гөнаһлылар кавемен һидәят итмәс»** («әл-Маидә», 108).



ХӘЗРӘТИ

# Адәм

*галәйһиссәләм*

### *Фәрештәләр сәҗдә кылырга тиеш булган*

## ХӘЗРӘТИ АДӘМ

### *галәйһиссәләм*

Мәңгелек Аллаһ Җәллә Җәләлүһү, бары үзе генә булганда, үзенә мәгълүм теләк белән, бөек сыйфатларының һәм илаһи исемнәренең ачылышы буларак, бу дөньяны яралта.

Җәнабел-Хакның без белә алган һәм белә алмаган барлык илаһи сыйфатларының иң күп беленә-күренә торган өч ачылу-беленү урыны бар:

а) Галәм;

б) Коръәни-Кәрим;

в) Кеше.

Галәм – илаһи исем-сыйфатларның гамәли, Коръәни-Кәрим исә – кәлами, сүздәге чагылышы. Башка сүз белән әйткәндә, Коръәни-Кәрим – сүз рәвешенә төренгән, сүз рәвешен алган бер галәм ул.

Кеше исә дөньяның теше, үзәге һәм орлыгы кебек, чөнки Аллаһның бөтен сыйфатларыннан да диярлек азмы-күпме өлеш чыгарылган бердәнбер җан иясе – кеше. Һәм аның мәхлукларның хөрмәтлесе, шәрәфлесе дип телгә алынуының сәбәбе дә шунда. Әмма аңарда Музилл[14], Мүтәкәббир[15] һәм шундый бөекле сыйфатлар белән бергә Һади[16], Рахман, Рәхим кебек күркәм сыйфатларның да чагылышы урын алганлыктан, бәндә табигате белән игелеккә дә, явызлыкка да авыша ала, чөнки аяти кәримәдә болай диелә:

وَنَفْسٍ وَمَا سَوّٰيهَا. فَأَلْهَمَهَا فُجُورَهَا وَتَقْوٰيهَا.
قَدْ اَفْلَحَ مَنْ زَكّٰيهَا. وَقَدْ خَابَ مَنْ دَسّٰيهَا

**«Җанга һәм аңа төрле сәләтләр биреп, аның күңеленә бозыклыкны һәм тәкъвалыкны салучы белән ант итәмен! Нәфесен гөнаһлардан арындырган кеше уңышка ирешкән. Аны фасикълык баткаклыгы эчендә яшергән кеше зарар күргән»** («әш-Шәмс», 7–10).

Шуңа күрә бәндә пәйгамбәрләр һәм әүлиялар нәсыйхәте ярдәмендә нәфесен тәрбияләп, йөрәген пакьләп, үзендәге түбән сыйфатлар һәм хирыслы-

14. Әл-Музилл – шуңа лаекларны юлдан яздыручы.
15. Әл-Мүтәкәббир – һәрнәрсәдә һәм гамәлдә бөеклеген һәм өстенлеген күрсәтүче.
16. Әл-Һади – һидәяткә ирештерүче.

клардан арыну, ә рухи сыйфатларын үстерү юлы белән камил кеше булырга тырышырга тиеш. Фәрештәләрнең явызлык кылуга ихтыяр-теләге һәм табигый сәләте булмаганга, кеше Аллаһ белән кавышу юлында хәтта аларны да узып китү мөмкинлегенә ия. Шунлыктан бәндә илаһи вәхиләргә буйсыну-иярүенә бәйле рәвештә, фәрештәдән өстен бөек дәрәҗәгә дә менәргә, хайваннардан да астарак түбәнлеккә дә төшәргә мөмкин. Нәфес киртәләрен үтеп чыга алган бәндә – күркәмлек көзгесе һәм искиткеч сәнгать әсәренә тиң. Дөнья китабының кыскача асылы башлану һәм яратылыш сереннән гыйбарәт, чөнки тышкы күренештә ит һәм сөяктән торуына карамастан, аның әлеге кыяфәтенә артына яшеренгән рухында илаһи чагылышның күпме серләре, нурлары һәм хакыйкатьләре тупланган.

Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе бу хакыйкатьне бер ике юллык шигырендә болай дип телгә ала:

«Дәваң – синдәдер, тик күрмәссең, Кайгың – синнәндер, тик белмәссең.

Үзеңне кечкенә бернәрсә санарсың, югыйсә, синдә иләмсез галәм тәрелгәндер».[17]

Бу мәсьәләдә иң мөһиме – барлык мәхлуклар өчен җыелган илаһи бөек аятьләрне уку һәм аларның чын мәгънәсен аңларга тырышу. Җәнабел-Хак Рәсүлуллаһка иңдергән тәүге вәхинең беренче аятендә: «Укы!» – дип боера. Монда кулланылган «кыйраәт» сүзе ниндидер язылган нәрсәне уку дигәнне генә белдерми, бер үк вакытта күз белән укуны һәм акылдан ятлап әйтү һәм уйлауга да ишарәли. Бу күзлектән караганда, аять түбәндәге мәгънәне белдерә: «Әй Рәсүлем! Илаһи сүзне укы, үзеңдәге һәм дөньядагы яшерен хакыйкатьләр турында уйла һәм истә калдыр, җисемнәрнең хакыйкый асылын аңларга тырыш».

Шушы мәгънәне күздә тотып, Мәснәвине шәрехләүчеләр мондый аңлатма язалар:

«Коръәни-Кәрим – “Укы!”; Мәснәви исә “Тыңла!” дип башлана. “اِقْرَأْ” сүзе “بِشْنَوْ” дигәннең тәфсире ролен үтәп: “Илаһи сүзне тыңла! Серләрне тыңла! Үзеңдә яшерелгән хакыйкатьне тыңла!” дигән мәгънә белдерә».

Кешенең бу дөньяда пәйда булуы Адәм галәйһиссәләмнән башлана. Тәүге кеше, тәүге пәйгамбәр һәм туры юлны күрсәтүче тәүге камил зат Адәм була. Кыяматкәчә дәвам итәчәк барлык кешелек нәселе тәүге яратылыш мизгелендә бер-берсе өстенә төшкән бихисап күләгәләр кебек аның шәхесенә бәйле, аның белән капланган. Әлеге хакыйкатькә ишарә итеп, аяти кәримәдә болай диелә:

17. Кайбер галимнәр кеше тәнендәге аерым органнар, табигатьтәге күренешләр һәм җисемнәр белән бәйләнеш күрәләр. Сөякләрне тауларга, төкләрне үсемлекләргә, кан тамырларын елгаларга, сулыш алуны җилләргә, сөйләшүне күк күкрәүгә... охшаталар. Ягъни табигатьнең кечерәйтелгән моделе булган кешедә, бер яктан караганда, табигать әсәре, аның йогынтысы да күзәтелә.

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِى خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ
وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً

**«И, кешеләр! Сезне бер җаннан** (Адәмнән) **яралткан, аның бер кисәгеннән** (Хәүва исемле) **ишен яралткан һәм аларның икесеннән бик күп ирләр белән хатыннарны бар кылып тараткан Раббыгыздан куркыгыз!..»** («ән-Ниса», 1).

Аллаһ Тәгалә кешене хөрмәтле кылганын һәм бөтен мәхлукаттан шәрәфлерәк яралтканын түбәндәгечә белдерә:

وَلَقَدْ كَرَّمْنَا بَنِي آدَمَ وَحَمَلْنَاهُمْ فِي الْبَرِّ وَالْبَحْرِ
وَرَزَقْنَاهُمْ مِنَ الطَّيِّبَاتِ وَفَضَّلْنَاهُمْ عَلَى كَثِيرٍ مِمَّنْ خَلَقْنَا تَفْضِيلًا

**«Тәхкыйк, Без Адәм улларын шәрәфле кылдык. Аларны** (төрле чаралар белән) **корыда һәм диңгездә йөрттек. Аларга яхшы-яхшы ризыклар бирдек һәм Без бар иткән мәхлукларның күбесеннән аларны өстен кылдык»** («әл-Исра», 70).

Шулай камил яратылган кеше илаһи кодрәтнең мең дә бер бизәге белән матурланган бу галәмдә илаһи сәнгатьнең иң югары дәрәҗәсен тәшкил итә. Бу үзенчәлекне Сөләйман Чәләби үзенең «Мәүлид»ендә болай тасвирлый:

«Хак Тәгалә чүн яратты Адәми,

Кыйлды Адәмлә мөзәййән галәми».

Адәмнең кечкенә бер галәмгә тиң булуы аркасында аның белән зур галәмгә әйләнгән дөнья асылы бер үк төрле хакыйкатьнең ике төрле мөмкинлектә аерым-аерым чагылышы булганлыктан, бер яфракның ике ягы, игезәк туганнар шикелле. Башка сүз белән әйткәндә, кеше дөньяның кечерәйтелгән моделе булганга күрә, табигатьтәге серләрне аңлау һәм әйберләрнең хикмәтен төшенүдә иң олуг вазифа аңа йөкләнә. Бер бодай бөртеге әлеге бодайның бөтен сыйфатларын үзенә туплаган, үзендә йөрткән кебек, һәм төрле орлыкның эчендә ул төрнең бөтен үзенчәлекләре һәм сыйфатлары саклана. Бәндә дә табигатьтәге һәрнәрсәнең хикмәтен үзенә туплаган гаҗәп зат булып тора. Бу яктан караганда, кеше, әйтерсең, табигатьнең эчендә төренеп яткан бер төш, орлык кебек. Әлеге хикмәт турында сөйләгәндә шәех Галиб болай ди:

«Күңел күзе белән кара әле үзеңә. Яралтылганнарның иң төбе син. Дөньяның күз бәбәге булган Адәм бит син».

Кешенең яралтылуында бик күп илаһи сәбәпләр бар, аларның берсе – Аллаһ Тәгаләнең яратылыш сәнгате һәм матурлыгына дәлил була алырлык

зат хасил итү теләге. Кешенең яратылуында илаһи теләк шулкадәр әһәмиятле ки, әлеге максат чынга аша алсын өчен, Җәнабел-Хак без төшенә алган һәм зиһенебез җитмәгән үзенчәлекләргә ия бөтен бер дөньяны хасил кыла һәм аны кешегә куллану-файдалану өчен тәкъдим итә.

Кеше җир йөзен үстерү-баету һәм күңелгә хуш әсәрләр барлыкка китерү өчен җаваплы, чөнки ул җирдә Аллаһның хәлифе булыр өчен яралтылган. Җәнабел-Хакның вәкиле сыйфатында яшәү, дигәнне белдергән әлеге хәлифлек вазифасы асыл табигатендә бу вазифаны тормышка ашырырдай сәләткә ия булу белән бәйле. Шытып чыгып үсәргә тиешле бер орлык кебек, бу теләк-ихтыярдан көтелгән нәтиҗә хасил була алсын өчен, кирәкле программаны, ягъни үз әмер һәм тыюларын Аллаһ Тәгалә Коръәни-Кәримдә хәбәр итә. Моңа тиешенчә буйсынганнарның рухи дәрәҗәләрен белдерү өчен, кодси хәдистә болай диелә:

*«Кем Минем вәли бер колыма дошманлык кылса, Мин аңа каршы сугыш игълан итәрмен. Колым Миңа иң күбе аңа Мин әмер иткән фарызларны башкарып якынаер. Фарызларга өстәмә кылган нәфел гыйбадәтләр белән дә якыная барыр, ахырда Мин аны сөярмен. Колымны сөйгәч исә, Мин аның ишетә торган колагы, күрә торган күзе, тотарга сәләтле кулы һәм йөрергә сәләтле аягы кебек булырмын. Миннән ни сораса, шуны, һичшиксез, бирермен. Миңа сыенса, Аны сакларымын»* (Бохари, «Рикак», 38).

Аяти кәримәдә:

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Барча мактаулар – галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка гына»**, – дип белдерелә («әл-Фатиха», 1). Хак Тәгалә бик күп галәмнәрне яралткан. Бу галәмнәрнең 18000нән 360000гә кадәр булу ихтималлыгы хакында риваятьләр бар. Бу риваятьләр бәндә гакылының галәмнәр санын күзаллауда чикләнгәнлеге сәбәпле, кинаяләп, читләтеп әйтү дип раслана ала. Барлык бу галәмнәрне: 1) бар ителгән (халикъ, матди) галәм; 2) әмер (рухи) галәм рәвешендә икегә бүлеп карарга мөмкин.

Аллаһ Тәгалә яралтканнарның бар ителгәннәр һәм әмер рәвешендә булганлыгы аяти кәримәдә түбәндәгечә раслана:

أَلَا لَهُ الْخَلْقُ وَالْأَمْرُ تَبَارَكَ اللّٰهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ

**«…Белеп торыгыз, бар кылу да, әмер бирү дә бары Аллаһка гына хас. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһ нинди бөек!»** («әл-Әгъраф», 54).

Бу аятькә мөнәсәбәттә мөфәссир Әлмалылы Хәмди Языр түбәндәгечә аңлатма бирә:

«Баштан ахыргача язмышны билгеләү һәм бар кылу да, кабул итү һәм шәригатьне билгеләү дә – Аның ихтыярында. Хәзерге хәлендә күләм-зурлыгы һәм саны бар мәхлуклар да – Аның милке, бу мәхлукларга даими килеп торган сансыз-хисапсыз әмерләр дә – Аныкы… Ягъни яралту да, идарә итү дә – Аңардан, җисем, матдә һәм форма да – Аның иҗаты һәм Аның хезмәт җимеше, алар белән идарә итүче куәт һәм рух та Аның тәэсире һәм көче була. Аннан башка берәү юклыктан бар да кыла алмый, мөмкинлеге булган бер мәхлукка нидер куша да алмый. Бар кылу – Аныкы,ваҗиб кылу – Аныкы, камиллек – Аныкы, Аллаһның үзеннән кала һәрнәрсә – Аның хөкемендә – Аның яралту һәм әмер итүенә бәйле. Ул исә һәрнәрсәне яралтучы һәм, һичшиксез, аны кулланучы, тәрбияләүче. Чынлыкта Аның иҗатына нигезләнмәгән һичнәрсә табылмас, Аның әмер һәм ихтыярына буйсынмаган идарә мөмкинлегенә дә юл куелмас».

Вакыт һәм урын белән чикләнгән хәлдә яралтылган мәхлуклардан гыйбарәт галәмне «халыйк (бар ителгән) галәм» дип атыйлар. Биш сизү әгъзаларыбыз белән тоя-күрә алган нәрсәләр – бу галәмнән.

Метафизик, рухи галәмне «әмер галәме» дип атыйлар. Бүтәнчә әйткәндә, әмер галәме – заман һәм матдә катнашыннан башка, Җәнабел-Хакның «бул» фәрманы белән генә хасил булган галәм ул. Аны мәләкут (Аллаһның маликлек урыны, җаннар һәм фәрештәләр галәме) һәм яшерен нәрсә галәме дип тә атыйлар. Акыл, нәфес, җан, күңел, сер һәм башка шундый төшенчәләр шушы галәмгә карый. Коръәни-Кәримдә:

قُلِ الرُّوحُ مِنْ أَمْرِ رَبِّي

**«…Әйт: Җан Раббымның әмереннән!..»** – дип («әл-Исра», 85), җанның да әмер галәменнән булганлыгы белдерелә.

Әлеге ике галәмдә яшәеш-хәрәкәттә булган ике аерым нәрсә яралтуга ишарә кылып, аяти кәримәдә болай диелә:

إِنَّمَا أَمْرُهُ إِذَا أَرَادَ شَيْئًا أَنْ يَقُولَ لَهُ كُنْ فَيَكُونُ

**«Ул берәр нәрсәне теләгән чакта, Ул аңа: “Бул!” – дип әйтүгә,** (ул) **шунда ук бар була»** («Йәсин», 82).

**Яралтылуыбызның төп сәбәп һәм хикмәтләре**

1. Кешенең яралтылуында төп максат – Җәнабел-Хакны тану һәм Аңа коллык (гыйбадәт) кылу.

وَماَخَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْاِنْسَ اِلَّا لِيَعْبُدُونِ

**«Мин җеннәрне**[18] **һәм кешеләрне бары Миңа коллык** (гыйбадәт) **кылсыннар өчен яралттым!»** – диелә аяти кәримәдә («әз-Зарият», 56).

Аятьтә яратылуның максаты буларак искә алынган «гыйбадәт» шундый хөрмәтле дәрәҗә ки, аның әлеге бөек урыны кәлимәи-шәһадәттә дә күренә. Мәсәлән, анда Пәйгамбәребезнең әүвәл «кол», аннары гына «рәсүл» булганлыгы әйтелә. Бу үзенчәлек тә коллыкның, гыйбадәтнең беренчелрәк, рәсүллекнең исә коллык кысаларында икәнен күрсәтә.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенә артык охшарга тырышкан затларга:

*«Сез мине хаклы дәрәҗәмнән югарырак күтәрмәгез! Чөнки Бөек Аллаһ мине рәсүл иткәнче, әүвәл кол итеп яралтты»*, – дип кисәтү ясап (Хәйсәми, IX, 21), коллыкның кыйммәтен, өстенлеген ассызыклый.

Башка аяти кәримәдә Аллаһ Тәгалә әйтә:

قُلْ مَا يَعْبَؤُا بِكُمْ رَبِّى لَوْلَا دُعَاؤُكُمْ

**«**(Рәсүлем!) **Әйт: Догагыз** (гыйбадәтегез һәм ялваруыгыз) **булмаса, Раббым сезгә ничек әһәмият бирсен?!** (Нинди кыйммәтегез бар!)**...»** («әл-Фуркан», 77).

Коллык бер мәгънәдә «мәгърифәтуллаһ» дигәнне белдерә, ягъни Җәнабел-Хакны тану һәм белү. Мәсәлән, Имам Матуриди рәхмәтуллаһи галәйһи иман өчен ике нигезне мәҗбүри дип саный:

**а) Мәгърифәтуллаһ.**

Кешенең яралтылуы «гыйбадәтен башкару» һәм «Җәнабел-Хакның тану» максатына туры килә, чөнки яратылуыбызның сәбәбенә мөнәсәбәтле рәвештә югарыда телгә алынган аяти кәримәдә «لِيَعْبُدُونِ» **«Миңа коллык кылсыннар өчен...»** («әз-Зарият», 56) дип әйтелә. Кайбер мөфәссирләр бу гыйбарәне «يَعْرِفُونِ», ягъни «Аллаһны тану, Раббыны йөрәк белән кабул итү аша мәгърифәтуллаһка ирешү» рәвешендә тәфсирләгән (Ибне Кәсир, «Тәфсир», IV, 255).

Кешенең яралтылуына иң беренче чиратта Җәнабел-Хак булуы һәм Аның үзен тануларын теләве сәбәп була. Чыннан да, кодси хәдис сыйфатында тапшырылган бер риваятьтә болай дип хәбәр ителә:

18. Кешенең асылы туфрактан яратылган булса, җеннәр төтенсез, якты уттан бар кылына. Аларның кер-пычрагы юк. Ләкин пычрак, шакшы булуы ихтимал затларның рәвешенә керү, аларның тәненә төренү сәләтләре бар. Яктылык рәвешендә хәрәкәт итү сәләтенә карамастан, җеннәр күп кенә мәсьәләләрдә кешеләр кебек камил мәхлуклар түгел. Дәрәҗәләре ягыннан кешеләрдән түбәнрәк торалар. Сөекле Пәйгамбәребез үзенә генә хас үзенчәлек буларак, кешеләргә дә, җеннәргә дә пәйгамбәр итеп җибәрелә. Шул сәбәпле, Аңа кешеләрнең һәм җеннәрнең рәсүле дигәнне белдергән «Рәсүлүс-сәкаләйн»; кешеләргә һәм җеннәргә фәтва бирүче Имам Газали, шәйхелислам Әбус-Согуд әфәнде һәм башка олуг ислам галимнәрен «мөфтиссәкаләйн», кешеләр һәм җеннәрне рухи тәрбиядә тырышлык куйган камил мөршидләрне «мөршидүссәкаләйн» дип атыйлар.

كُنْتُ كَنْزًا مَخْفِيًّا فأَحْبَبْتُ اَنْ اُعْرَفَ فَخَلَقْتُ الْخَلْقَ لاِعْرَفَ

*«Мин яшерен хәзинә идем. Мине белүләрен теләдем (Үземне тануларын сөйдем) дә (бу) дөньяны яралттым …»* (И. Хаккы Бурсеви, «Кәнзи махфи»).[19]

**б) Мәхәббәт.**

Җәнабел-Хак аяти кәримәдә болай ди:

وَالَّذِينَ آمَنُوا أَشَدُّ حُبًّا لِلَّهِ

**«…Иман китерүчеләрнең Аллаһны сөюләре һәрнәрсәдән көчлерәк һәм артыграк…»** («әл-Бәкара», 165).

Димәк, яралтылуыбызның иң төп сәбәп һәм хикмәтләренең тагын берсе – Җәнабел-Хакны һәрнәрсәгә караганда да ныграк сөюдән гыйбарәт, чөнки Ул безне сөя, хисабыбыз җитмәс дәрәҗәдә нигъмәтләр бирә, һәм, моның бер нәтиҗәсе буларак, колларыннан барыннан да бигрәк Олуг Затны яратуларын һәм Аллаһка мәхәббәтнең башка мәхлукларга карата сөю хисеннән көчлерәк булуын тели. Әгәр инде моңа каршы килсәләр, андый мөнәсәбәтнең зур кайгы-хәсрәт, куәтле газапка китерәчәге белдерелә. Бу мәсьәлә белән бәйле аяти кәримәдә мондый кисәтү ясала:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا مَنْ يَرْتَدَّ مِنْكُمْ عَنْ دِينِهِ فَسَوْفَ يَأْتِى اللّٰهُ بِقَوْمٍ يُحِبُّهُمْ وَيُحِبُّونَهُ

**«Әй иман китерүчеләр! Арагыздан кем дә булса диненнән** (чыгып, кире кяферлегенә) **кайтса, Аллаһ алар урынына бер җәмәгать китерер, Аллаһ үзләрен сөя, алар да Аны сөя…»** («әл-Маидә», 54).

Бүтән бер аяти кәримәдә дә бәндәләрнең һәм кавемнәрнең һәлак ителүендә «мәхәббәтнең өзелүе» гадәттә тәүге сәбәп икәнлеге белдерелә:

قُلْ إِنْ كَانَ آبَاؤُكُمْ وَأَبْنَآؤُكُمْ وَإِخْوَانُكُمْ وَأَزْوَاجُكُمْ وَعَشِيرَتُكُمْ وَأَمْوَالٌ اقْتَرَفْتُمُوهَا
وَتِجَارَةٌ تَخْشَوْنَ كَسَادَهَا وَمَسَاكِنُ تَرْضَوْنَهَا أَحَبَّ إِلَيْكُمْ مِنَ اللّٰهِ وَرَسُولِهِ وَجِهَادٍ فِى
سَبِيلِهِ فَتَرَبَّصُوا حَتَّى يَأْتِيَ اللّٰهُ بِأَمْرِهِ وَاللّٰهُ لَا يَهْدِى الْقَوْمَ الْفَاسِقِينَ

**«Әйт: “Әгәр сезнең аталарыгыз, улларыгыз, кардәшләрегез, хатыннарыгыз, гаиләләрегез, кәсеп иткән малларыгыз, торгынлыкка төшүеннән курыккан сәүдәгез һәм күңелегезгә якын торакларыгыз сезгә Аллаһтан, Аның Рәсүленнән һәм Аның юлында җиһад кылудан сөеклерәк икән,**

19. Шулай ук карагыз: Әбус-Согуд, «Иршадүл-Аклис-Сәлим», II, 130; Аҗлуни, «Кәшфүл-Хафа», II, 132.

**Аллаһның сезнең хакта** (газап) **әмере китергәнен көтегез. Аллаһ фасикълар кавемен һидәяткә ирештермәс"»** («әт-Тәүбә», 24).

Хәдис-шәрифтә исә иман тәмен бары түбәндәге өч шартка туры килгән зат кына татып карый алачагы белдерелә:

– *«Аллаһны һәм Аның Рәсүлен һәрнәрсәдән ныграк ярату*;

*– Иманга килгәннән соң, көферлеккә төшүне утка эләгү кебек куркыныч нәрсә итеп күрү*;

*– Аллаһ (ризалыгы) өчен сөю һәм Аллаһ (ризалыгы) өчен нәфрәт тою»* (Бохари, «Иман», 9, 14; Мөслим, «Иман», 67).

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ихлас итагать, Аңа иярү һәм гайре көчле мәхәббәт Аллаһка карата мәхәббәтнең шарты булып тора. Җәнабел-Хак үз Китабында болай ди:

قُلْ إِنْ كُنْتُمْ تُحِبُّونَ اللّٰهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللّٰهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ وَاللّٰهُ غَفُورٌ رَحِيمٌ

**«**(Әй Рәсүлем!) **Әйт: "Әгәр сез Аллаһны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһ та сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһ – Гафур, Рәхимдер"»** («Әли Гыймран», 31).[20]

Хәдис-шәрифтә дә Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мәхәббәт хак иманның шарты буларак искә алына:

*«Җаным Аның кодрәтендә булган Аллаһ белән ант итәм, сездән берегез, мин аңа анасыннан, атасыннан, баласыннан һәм бөтен кешеләрдән сөеклерәк булмыйча торып, чын мәгънәсендә иман китергән булмас»* (Бохари, «Иман», 8).

2. Үзенең яралту, бар итү сыйфатындагы бөеклеген һәм тиңсезлеген, ягъни сәнгатенең олуглыгын күрсәтү өчен, Җәнабел-Хак кешене яралта. Чөнки кеше – сокланугa лаек яралту нәтиҗәсе һәм иҗат әсәре. Чыннан да, «Зәрият» сүрәсенең 20–21 аятьләрендә болай диелә:

وَفِي الْأَرْضِ آيَاتٌ لِلْمُوقِنِينَ. وَفِي أَنْفُسِكُمْ أَفَلَا تُبْصِرُونَ

**«Шиксез ышанганнар өчен җирдә аятьләр бар. Һәм үзләрегездә дә Аллаһның бөеклеген күрсәткән дәлилләр бар. Һаман күреп тә уйлап карамыйсызмы?»**

Җәнабел-Хак башка бер аяти кәримәдә дә кешенең бар ителү этапларын белдергәннән соң, үзенең бөеклеге турында түбәндәгечә җиткерә:

20. Әл-Гафур – бөтен гөнаһларны гафу итүче. Әр-Рәхим – гафу итеп, ярлыкаучы, киң мәрхәмәт иясе, мөэминнәрне ахирәттә бүләк белән сөендерүче.

فَتَبَارَكَ اللَّهُ أَحْسَنُ الْخَالِقِينَ

**«…Яралтучының[21] иң күркәме булган Аллаһ – бик бөек!»** («әл-Мүэминүн», 14).

Кешенең яралтылу нәтиҗәсе булуының башка тарафы исә аның иң шәрәфле мәхлук һәм Җәнабел-Хакның җирдәге хәлифе итеп билгеләнүендә.

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً

**«Менә Раббың фәрештәләргә: “Мин җирдә хәлиф яралтачакмын!” – дип әйткән иде...»** – дип хәбәр ителә аяти кәримәдә («әл-Бәкара», 30).

Мөфәссир Әлмалылы Хәмди Язып аяти кәримәдәге «хәлиф яралтачакмын» гыйбарәсен түбәндәгечә тәфсир кыла:

«Үз ихтыярымнан, кодрәт һәм сыйфатымнан аңа кайбер сәләтләр бирәчәкмен; ул Миңа бәйле рәвештә, Минем вәкилем буларак мәхлукларым өстеннән бер төркем мөмкинлекләргә ия булачак; Минем исемемнән хөкемемне тормышка ашырачак; ул бу мәсьәләдә төп зат түгел; ул үз исеме, үз шәхесе исеменнән хөкем йөртмәячәк, бары Минем бер вәкилем булачак. Ул үз ихтыяр-теләге белән Минем теләгемне, Минем әмерләремне, Минем кануннарымны чынга ашыручы җаваплы зат булачак. Соңыннан аның дәвамчылары, нәселе һәм аңа хәлиф буларак шул ук вазифаны башкаручылар табылачак, **“Ул (**Аллаһ Тәгалә**) сезне җирдә хәлифләр кылды”** («әл-Әнгам», 165) җөмләсенең сере ачылачак» (Әлмалылы, «Хак Дини Куран Дили», I, 299–300).

Чыннан да кеше Хак Тәгаләгә якынлык ягыннан хәтта фәрештәләрне дә көнләштергән сыйфат һәм үзенчәлекләр белән яралтыла. Әлеге хакыйкать аяти кәримәдә түбәндәгечә белдерелә:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنْسَانَ فِي أَحْسَنِ تَقْوِيمٍ

**«Һичшиксез, Без кешене иң күркәм сурәттә яралттык»** («әт-Тин», 4).

3. Җәнабел-Хак кешене үз илаһи исем-сыйфатларның чагылышын өстенрәк дәрәҗәдә күрсәтү өчен яралта.

*«Аллаһ Тәгаләнең әхлагы белән әхлакланыгыз»* (Мөнави, «әт-Тәгариф», 564 б.) хәдис-шәрифе дә шушы хасияткә ишарәле. Чөнки илаһи исем-сыйфатларның иң күп, иң ачык чагылышы мәхлуклардан нәкъ менә кешедә күзәтелә.

21. Гарәп телендә «халикъ» – яралту сүзе «бернәрсә иҗат итү, ясау» мәгънәсен дә белдергән өчен, башка мәхлукларга карата да кулланыла ала. Шунлыктан «Әхсәнүл-халикин – Яралтучының иң күркәме», дигәндә, Аллаһтан башка да бер яралтучы бар, дигәнне белдерми. Мәсәлән, «укучыларның иң яхшысы – Гали», дигәндә, сыйныфта Гали белән бергә башка яхшы укучыларның да булуы мәҗбүри шарт түгел. Сыйныфта бердәнбер яхшы укучы Гали булса да, бу гыйбарә кулланыла ала һәм ул «Гали – бик яхшы укучы» мәгънәсен белдерә.

Фәрештәләргә кибрия (тәкәбберлек) һәм музилл кебек сыйфатлар гомумән хас булмаганга күрә, аларга нәфес комачауламый, алар гөнаһ кылмый. Шул сәбәпле нәфес котыртуын, нәфес киртәсен җиңеп, Аллаһ белән кавышу һәм Аның хәлифе булу мөмкинлеге бары тик кешегә генә насыйп ителгән.

Хактан да, шәрәфле мәхлук булган Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Мигъраҗда фәрештәләрнең иң олысы, дәрәҗәлесе булган Җәбраил галәйһиссәләм дә уза алмаган чикне, ягъни Сидратүл-Мүнтәханың аръягына үткәрелә.

Азиз Мәхмүт Һүдайи хәзрәтләре кешенең галәмгә бар ителүен һәм бу галәмнән кабат Хак Тәгаләгә кайтуын ничек матур тасвирлый:

«Мәңгелектән гашыйклык белән без янә килдек! Хакыйкать шәмenә күбәләктәй килдек!

Аллаһ Тәгаләнең бердәнбер галәменнән иңеп, бу муллык дөньясын гизәргә килдек!

Фәрман белән кичеп күп галәмнәр, йөри-йөри кешелек галәменә килдек!

Үлемле булды вакытлы вөҗүд, һичшиксез, ташлап тамчыны, килдек зур диңгезгә!

Ходай, Сиңа нәрсәбез лаек? Шундук бер күркәмлек белән ихсанга килдек!

Ышанам, кайтыйк бакый тормышка,

Хәзрәти Рахман янына килдек!

Узып бу муллык галәменнән, Бердәнбер Ходай катына килдек!»

Кыскасы, бәндә, дөньяга җибәрелү максатын төшенеп, гомерен Җәнабел-Хак аңа биргән хисапсыз нигъмәтләргә чиксез рәхмәт хисе белән, бер Аллаһ колы булып кичерергә тиеш.

**Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмнең яралтылуы**

Дөньяны яралтучы һәм аның хөкемдары булган Аллаһ Тәгалә, үзенең барлыгын белсеннәр, гыйбадәттә һәм итагатьтә булсыннар, җир йөзен матурлап кору өчен, мәхлукларның иң шәрәфлесе итеп кеше яралту турында чиксез хыяллана. Әүвәлрәк бар кылган һәм үзләренә бары тик гыйбадәт кылу вазифасын гына йөкләгән фәрештәләргә бу илаһи ниятен болай дип бәян итә:

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي جَاعِلٌ فِي الْأَرْضِ خَلِيفَةً قَالُوا أَتَجْعَلُ فِيهَا مَنْ يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ قَالَ إِنِّي أَعْلَمُ مَا لَا تَعْلَمُونَ

**«Менә Раббың фәрештәләргә: ”Һичшиксез, Мин җирдә хәлифә яралтачакмын!” – дип әйткәч, алар: “Әллә җирдә бозыклык кылучыны һәм кан коючыны яралтачаксыңмы? Без бит һәрвакыт Сиңа мактау белән тәсбих әйтәбез, олылыйбыз”, – диделәр. Ул: “Һичшиксез, Мин сез белмәгәннәрне беләм!” – диде»** («әл-Бәкара», 30).

Аллаһның бу сүзләренә каршы фәрештәләр беравыздан:

قَالُوا سُبْحَانَكَ لَا عِلْمَ لَنَا إِلَّا مَا عَلَّمْتَنَا إِنَّكَ أَنْتَ الْعَلِيمُ الْحَكِيمُ

**«”Йә Раббы, Син һәр кимчелектән пакь! Бездә һич белем юк, мәгәр Син безгә өйрәткәнне генә беләбез. Һичшиксез, Син генә – Галим, Хаким[22]”, – диделәр»** («әл-Бәкара», 32).

Хәлифлек, вәкиллек кебек вазифа аз дәрәҗәдәме, күптәме, бу вәкаләт бирүчене алыштыру, аның урынын тоту дигән сүз. Монда «хәлиф» сүзе «вәкил» мәгънәсен белдереп, Аллаһның теләк-ихтыярына җир йөзендә вәкил булып чыгыш ясаучы, Аның кушканнарын һәм тыйганнарын үтәүче дигәнне аңлата. Шуңа күрә бәндә Аллаһның нуры тәмамлануга бер чара һәм сәбәп булачак.[23]

Вәкаләт шул ук вакытта аны бирүченең үз вәкиленә билгеле бер хөрмәт, дан бүләк итеп, аны хөрмәтләвен дә белдерә. Җәнабел-Хакның үз пәйгамбәрләрен җирдә хәлиф итеп куюы да шул хисаптан карала ала. Асылда, кешегә өрелгән җанда да мондый бер әмирлек, ягъни идарә итү сыйфаты бар. Югыйсә бу хәлифлек берничек тә «илаһи вәкаләт» белдерә алмый..

Бу аяти кәримәдә Җәнабел-Хакның фәрештәләр белән бертөрле киңәш-табышы турында сөйли һәм, Аллаһ Тәгалә бер хәлиф зат яралтачагын хәбәр иткәч, фәрештәләр чынлыкта, үзләренең моңа лаеклырак икәнен сиздерергә тырыша, Аллаһны бик күп тәсбих иткәннәрен, һәрчак мактаганнарын белдерәләр. Әмма Җәнабел-Хак: **«Мин сез белмәгәннәрне дә беләм»**, – дип, бер яктан караганда, бу тәсбихләрнең, хәмед-сәнәләрнең хәлифлек өчен җитәрлек түгеллеген, үзеннән җан өрү гамәленең һәм күркәм исемнәрне өйрәтүнең моңа бер сәбәп булачагын аңлата.

Димәк, бәндә бер иҗат, илаһи сәнгать җимеше булып, яшерен яклары белән дә, ачыклары белән дә хәлифлеккә лаек. Аллаһның бөтен исем-сыйфатларының диярлек үзендә камил чагылышы булган мөкәммәл мәхлук ул.

22. Әл-Галим – мәңгелек гыйлеме белән инде булган һәм булачак һәрнәрсәне белүче. Хаким – бөтен әмер һәм гамәлләре тиешле урында булучы.
23. Чыннан да, Җәнабел-Хак Имам Әгъзам, Имам Бохари, Әхмәд ибне Ханбәл хәзрәтләрне, башка мәзһәп һәм тәсаувыф башлыклары кебек шәхесләрне кыямәткәчә Аның дине дәвам итсен, саклансын өчен бер сәбәп итеп кылган.

**Фәрештәләрнең Җәнабел-Хакка сорау бирү хикмәте**

1. Фәрештәләр кешенең яралтылыш хикмәте нидә икәнлеген белергә теләми. Чынлыкта бу баш күтәрү, каршы килү булмый, аларның Хәзрәти Адәмнән көнләшүләре дә түгел. Чөнки изге китап белдергәнчә, фәрештәләрдә Аллаһка каршы килү, буйсынмау гадәте, көнчелек һәм нәфрәт кебек начар холык сыйфатлары юк.

2. Фәрештәләр кешенең җирдә фетнә чыгарып, кан түгәчәген ләүхел-мәхфүздән белеп алган булулары ихтимал. Шуңа күрә мондый сорау бирергә мөмкиннәр. Мәсәлән, кайбер Коръән белгечләре фәрештәләрнең ләүхел-мәхфүзне күрә, укый алулары турында белдерә.[24]

3. Хак Тәгалә бу хәл турында аларга әүвәлрәк хәбәр иткәнгә күрә, мондый сорау биргән булырга мөмкин.

4. Башка бер карашка күрә, фәрештәләр җеннәрнең бозым чыгаруы һәм фетнә чыгарулары турында алдан ук белгәнгә күрә, бу сорауны биргәннәр.

Риваятьтә сөйләнгәнчә, Аллаһ Тәгалә Адәм галәйһиссәләмне яралтырга теләгән вакытта җир йөзенә:

«Мин синең туфрагыңнан үземә хәлиф яралтачакмын. Алардан миңа итагать итүчеләр вә буйсынмаучылар булачак. Миңа итагать кылучыларны – җәннәткә, гыйсьянчыларны исә җәһәннәмгә ташлаячакмын», – дип дәшә.

Аннары Аллаһ Тәгалә дүрт фәрештә: Җәбраил, Микаил, Исрафил һәм Газраил галәйһимәс-сәләмнәрне бер-бер артлы җир йөзенә җибәрә. Аларга төрле җирләрдән берәр уч туфрак алып килергә куша. Фәрештәләр бу әмерне үтәү өчен, җир йөзенә иңгәч, җир:

«Сез алачак бу туфрактан кеше яралтылачак һәм ул Аллаһка каршы баш күтәрәчәк, шунлыктан җәһәннәмгә керәчәк. Нәтиҗәдә минем бер кисәгем җәһәннәмдә яначак!» – дип, туфрагын бирмәскә тели.[25]

24. Карагыз: Рази, «Тәфсир», XXXI, 114.
25. Җансыз дип белгән нәрсәләр үзләренә йөкләнгән бурыч-вазифаларның авырлыгын белерлек дәрәҗәдә аң-зиһенгә ия булганлыгы аңлашыла. Чыннан да, Пәйгамбәребез галәйһис-саләтү вәссәләәм бервакыт Хәзрәти Әбүбәкер, Гомәр һәм Гали радыйаллаһу ганһүм белән бергә Өхед тавына менә. Өхед тетри башлый. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәллəм: «Тыныч бул, әй Өхед! Өстеңдә бер пәйгамбәр, бер сиддыйк һәм ике шәһид бар!» – дип боера (Тирмизи, «Мәнакыйб», 18/3703).
Җансыз нәрсәләр, үсемлекләр һәм хайваннарның һәркайсы үз телләрендә Раббыларына тәсбих һәм хәмед-сәнәләр әйтә. Бу үзенчәлек аяти-кәримәдә түбәндәгечә искә алына:
«Җиде күк белән җир һәм аларда булганнар Аңа тәсбих әйтеп торалар. Аны мактау белән мактамаган һичбер нәрсә юк, ләкин сез аларның тәсбихләрен аңламыйсыз. Һичшиксез, Ул – Мәрхәмәтле һәм Гафу итүче» («әл-Исра», 44).
Хөрмә төбенең Пәйгамбәребезне сагынып сызлануы (Бохари, «Мәнакыйб», 25), Кызыл диңгезнең Хәзрәти Муса белән Фиргавенне аеруы («әл-Бәкара», 50) – моңа иң күркәм үрнәкләр.
Тагын бер мисал. Япон галиме Масару Эмото, туңган су кристалларын өйрәнгәндә, аларның тигез, матур алтыпочмаклык формасында барлыкка килүен һәм кеше кулы кагылмаган чишмә суларында бу кристалларның адәм баласын сокландырырлык тигез һәм матур формага ия булуын бил-

Шуннан соң Җәбраил, Микаил һәм Исрафил галәйһимәс-сәләмнәр җирдән бернәрсә дә ала алмыйча, Раббылары янына кайтып, болай диләр:

«Я Раббы, җир Сиңа сыгынды, җәһәннәмдә яндырыр өчен туфрагын бирүдән баш тартты. Без исә аны мәҗбүриләүне дөрес түгел дип белдек!»

Тик Газраил галәйһиссәләм җирнең бу сүзләренә: «Мин исә Аллаһның әмерен үтәмичә Аның янына кайтудан Аның үзенә сыгынам», – дип каршы килә һәм җирнең төрле урыннарыннан төрле төсләрдәге – кызыл, ак һәм кара туфраклар ала. Аннары, аларны катыштырып, Җәнабел-Хакка тапшыра. Газраил галәйһиссәләмгә, шушы карарлылыгы, үҗәтлеге аркасында, җан алу вазифасы бирелә.[26]

Туфрактан яралтылганга күрә, кеше туфрак сыйфатларына ия. Туфрак вакыт-вакыт корый-кибә, эсседән куырыла, дымга сусый. Бер фасылны кышның авырлыклары алыштыра: бәрәкәтле яз яңгырлары белән ул яңадан терелә. Мең дә бер матурлык, төсләр, исләр һәм көй-аһәңнәре белән илаһи кодрәт бизәкләрен күрсәтә.

Кешенең дә язмышы туфракныкына охшаш. Ул дөньяви теләкләр бөтерчегендә чүлләрдәге ком бураннары кебек селкенеп, бөтерелеп йөри. Нәфес басымы астында тәртибен, әдәп-әхлагын боза, ләкин нәфес киртәсен җиңеп чыгу нәтиҗәсендә камилләшә. Туфрак язгы яңгырлар белән тормышка кайткан кебек, гыйлем алып, рәхмәтле гамәлләр кылып, башкаларны кайгырта башлый. Шул рәвешле үзенә килгән нигъмәтләрне, бер язның муллыгы һәм бәрәкәте кебек, уңдырышлы туфраклар үрнәгендә, Аллаһ ризалыгы өчен, тирә-янындагыларны туендырыр.

Бәндәнең фани гәүдәсе туфрактан яралтылганга күрә, туфрак белән ризыклана һәм ахыр чиктә туфракта юкка чыгар. Ягъни үзенең асылына кайта. Туфрактагы бөтен элементлар азмы-күпме дәрәҗәдә кеше тәне составына керә. Кеше тәне – шул ук вакытта туфракның башка төрле формасы, күренеше ул. Әйтик, бер риваятьтә болай диелә: Адәм галәйһиссәләм туфрактан ярал-

---

гелән үтә. Ул бу суларны аерым-аерым ике савытка алып, тәҗрибә уздыра. Беренче савыт өстенә догалар һәм рәхмәт сүзләре, мәхәббәт, мәрхәмәт тулы гыйбарәләр әйтелә, андагы су кристаллары үзләренең табигый матурлыгын саклый. Икенче савытка кимсетү сүзләре әйтелә, «шайтан» кәлимәсе тәкрарлана. Галим андагы кристалларның җимерелгәнлеген, аларның формасы бозылганлыгын, бөтен эстетик матурлыкларының беткәнлеген күрә. Шул ук экспериментта суга матур һәм күңелгә хуш музыка белән ямьсез, тынычсызлый торган ритмнар да төрлечә тәэсир ясый.

Үзе ирешкән нәтиҗәне тагын да үстерү-ныгыту өчен, Масара Эмото шундый ук тикшеренүне пешкән дөге белән дә үткәрә. Ул дөгене аерым банкаларга сала. Аларның берсенә «рәхмәт», икенчесенә «тиле» дип язылган кәгазь куела. Шул ук сүзләр бер ай дәвамында банкалар өстендә кабатлана. Галим рәхмәт сүзе ишетеп торган беренче банкадагы дөгенең үз аклыгын һәм сафлыгын саклап калуын, икенче банкадагы дөгенең, караланып, начар ис чыгара башлавын ачыклый (М. Акиф Дениз, «Беренче адым», февраль, 2003).

26. Карагыз: Табәри, «Тарих», I, 89–90.

тылганга күрә, «Адәм» дип исем бирелә.[27] Адәм галәйһиссәләмнең туфрактан яратылуы аяти кәримәдә:

إِنَّ مَثَلَ عِيسَى عِنْدَ اللّٰهِ كَمَثَلِ آدَمَ خَلَقَهُ مِنْ تُرَابٍ ثُمَّ قَالَ لَهُ كُنْ فَيَكُونُ

**«...Аллаһ аны туфрактан яралтты. Соңыннан аңа: "Бул!" – диде** (һәм ул) **бар булды»**, – дип телгә алына («Әли Гыймран», 59).

Туфрак кызыл, кара, ак һәм башка төсләргә ия булган кебек, аннан яралтылган адәм балалары да төрле төстә. Шулай ук туфракның каты һәм йомшак яклары булган кебек, кешеләр дә сәләт һәм холык мәсьәләсендә бик төрле. Әлеге хакыйкатьне аяти кәримә болай хәбәр итә:

أَلَمْ تَرَ أَنَّ اللّٰهَ أَنْزَلَ مِنَ السَّمَاءِ مَاءً فَأَخْرَجْنَا بِهِ ثَمَرَاتٍ مُخْتَلِفًا أَلْوَانُهَا وَمِنَ الْجِبَالِ جُدَدٌ بِيضٌ وَحُمْرٌ مُخْتَلِفٌ أَلْوَانُهَا وَغَرَابِيبُ سُودٌ. وَمِنَ النَّاسِ وَالدَّوَابِّ وَالْأَنْعَامِ مُخْتَلِفٌ أَلْوَانُهُ كَذٰلِكَ إِنَّمَا يَخْشَى اللّٰهَ مِنْ عِبَادِهِ الْعُلَمٰٓؤُا إِنَّ اللّٰهَ عَزِيزٌ غَفُورٌ

**«Аллаһның күктән суны иңдергәнен күрмәдеңме? Аның белән Без төрле төсләрдәге җимешләр чыгардык. Тауларда да төсләре төрле-төрле – аклары, кызыллары һәм башка төсләрдә булган юллар** (ясадык). **Кешеләрдән, җанлылардан һәм терлекләрдән дә төсләре төрле-төрле булганнар бар. Коллары арасыннан галимнәр генә Аллаһтан** (тиешенчә) **курка. Һичшиксез, Аллаһ – Бөек, Гафу итүче»** («Фатыйр», 27–28).

Бу мәсьәләдә Рәсүл Әкрәм саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

*«Аллаһ Тәгалә Адәмне җирнең һәр тарафыннан алган бер тотам туфрактан яралткан. Шул сәбәпле Адәм балаларының, шул туфрак белән бәйле рәвештә, бер өлеше кызыл, бер өлеше ак һәм кара, бер өлеше исә катнаш төстә; бер өлеше йомшак, бер өлеше кырыс, бер өлеше яхшы холыклы, бер өлеше начар холыклы (ягъни төрле холыклы, үзенчәлекле һәм төрле сәләтле) булып дөньяга килә»* (Әбү Давыт, «Сөннәт», 16).

Риваятьтә әйтелгәнчә, *«Аллаһ Адәм бар ителәчәк туфракны кырык көн изә»* (Табәри, «Тәфсир», III, 306). Бу көннәрдән һәрберсе без аңлый-төшенә алмаган вакыт берәмлеге булып тора.

Чыганаклардагы мәгълүматларга караганда, Адәм яралтылган балчык кырык ел үз хәлендә кала. Билгеле бер калыпта пешә. Өстенә утыз тугыз ел борчу-кайгы яңгыры, бер ел шатлык-куаныч яңгыры ява.[28] Шуңа күрә адәм

27. Карагыз: Ибне Сәгъд, «Табакат», I, 26.
28. Карагыз. Бурсәви, «Рухул-Бәян», I, 99 («әл-Бәкара», 31).

баласының борчу-кайгылары сөенечләрдән күбрәк. Шагыйрьләр сүзе белән әйткәндә:

هَا هِيَ الدُّنْيَا اِذَا أَضْحَكَتْ يَوْمًا أَبْكَتْ اَيَّامًا

«Менә шундый дөнья! Әгәр бер көн көлдерәчәк икән, атналарча елатыр».

Югарыда искә алынган бу яңгыр ниндидер матди нәрсә, чын яңгыр түгел, абстракт төшенчә, яңгыр сүзе күчерелмә мәгънәдә кулланылган.

Кайгы-борчудан соң һәрвакыт сөенеч килә. Олуг нигъмәт-бүләкләр – зур сабырлык һәм кайгы-хәсрәтләрдән соң. Мигъраҗ могҗизасының авыр һәм хәсрәтле Таиф сәфәреннән соң бүләк ителгәнлеге, газаплы Мәккә чорыннан соң бәхетле Мәдинә чоры килгәнлеге кебек...

Аяти кәримәдә Аллаһ Тәгалә әйтә:

فَإِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا إِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا

**«Һичшиксез, авырлыктан соң җиңеллек бар. Чынлыкта да, авырлыктан соң җиңеллек бар»** («әл-Инширах», 5–6).[29]

«Инширах» сүрәсе иңдерелгәндә, Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Җәнабел-Хакның бер авырлыкка каршы ике җиңеллек җибәрелүенә бик сөенә, шатлыклы көләч йөз белән:

لَنْ يَغْلِبَ عُسْرٌ يُسْرَيْنِ: إِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا إِنَّ مَعَ الْعُسْرِ يُسْرًا

**«Бер кыенлык ике җиңеллектән һич өстенрәк була алмас, чөнки, һичшиксез, бер авырлыктан соң җиңеллек бар. Чынлыкта да, авырлыктан соң тагын бер җиңеллек бар»**, – дип («әл-Инширах», 5–6), сәхабәләре янына килә (Хаким, II, 575).

Тормыш мәшәкатьләре каршында авыр хәлдә калган затларга бәладән чыгу юлы күрсәтеп, бер шигырьдә:

«Ниндидер авырлыкка тарыганда, “Инширах” сүрәсендәге тирән мәгънә турында фикерләп кара! Анда бер кыенлык ике җиңеллек арасында телгә алына. Бу хакта яхшылап уйлагач, кайгы-борчуларың таралыр, хәсрәтең бетәр», – дип әйтелә.

29. Бу аятьләрдә «гуср» (авырлык) һәм «йуср» (җиңеллек) сүзләре кабатлана. Ләкин «гуср» «әлимләм» артикле белән билгеле нәрсә буларак искә алына, ә «йуср» билгесезлек артикле белән кулланыла. Гарәп теле кагыйдәләре буенча, билгеле сүз кабатланса, ул бер үк нәрсәне белдерә, ә билгесезлек артикле белән килгән сүз кабатланганда, ул төрле нәрсәне белдерә. Шунлыктан,»гуср» сүзенең ике тапкыр кабатлануына карамастан, бер авырлыкны гына белдергән булып чыга, «йуср» исә ике җиңеллек дигән сүз (Карагыз: Бохари, «Тәфсир», 94).

Һичшиксез, дөнья – төрледән-төрле кыенлык-газаплар белән тулы сынау мәйданы ул. Аяти кәримәдә бу мәсьәлә белән бәйле рәвештә болай диелә:

وَلَنَبْلُوَنَّكُمْ بِشَيْءٍ مِنَ الْخَوْفِ وَالْجُوعِ وَنَقْصٍ مِنَ الْأَمْوَالِ وَالْأَنْفُسِ وَالثَّمَرَاتِ وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ. اَلَّذِينَ إِذَا أَصَابَتْهُمْ مُصِيبَةٌ قَالُوا إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعونَ. أُولَئِكَ عَلَيْهِمْ صَلَوَاتٌ مِنْ رَبِّهِمْ وَرَحْمَةٌ وَأُولَئِكَ هُمُ الْمُهْتَدُونَ

**«Без, һичшиксез, сезне бераз курку белән, бераз ачлык белән һәм малларыгызга, җаннарыгызга, уңышларыгызга бераз зыян китерү белән сыныйбыз.** (Әй Рәсүлем!) **Сабыр итүчеләрне сөендер! Берәр бәлагә юлыкканнар: "Һичшиксез, без – Аллаһныкылар һәм Аңа гына кайтачакбыз!" – дип әйтәләр. Әнә шулар – Раббыларының мәгъфирәтенә һәм рәхмәтенә ирешүчеләр, һәм әнә шулар гына – һидәят табучылар»** («әл-Бәкара», 155–157).

Җансыз предметларга һәм үсемлекләргә дә гомуми сабырлыктан соң өлгерү, җитлегү чоры хас. Туфрак кыш фасылында газап чиккәннән соң, яз килә. Кеше дә кыенлыклар һәм сабырлык аша җитлегә, камилләшә.

Коръәни-Кәримдә Хәзрәти Адәмнең туфрактан яралту этаплары түбәндәгечә аңлатыла:

**1. Туфрак этабы.**

خَلَقَهُ مِنْ تُرَابٍ ثُمَّ قَالَ لَهُ كُنْ فَيَكُونُ

**«...**(Аллаһ) **Адәмне туфрактан яралтты, соңыннан аңа: "Бул!" – дип әйтте, һәм ул бар булды»** («Әли Гыймран», 59).

Кеше туфрактан яралтылганга күрә, туфракның төрле сыйфатларына ия. Туфрак үзле, комлы, каты, йомшак булган кебек, кешеләрнең холык-табигатенә төрлелек хас. Балчык бик яхшы изелә, аның белән бик җиңел теләсә нәрсә ясап була. Балчык моңа бернинди дә каршылык күрсәтми. Кешедәге сабырлык, түземлек һәм кече күңеллелек әнә шуннан килә. Шул ук вакытта туфракның хәрәкәтсезлеге, тик торуы кешедә ялкаулык, иренү кебек сыйфатларда чагылыш тапкан.

**2. Юеш балчык этабы.**

اَلَّذِي أَحْسَنَ كُلَّ شَيْءٍ خَلَقَهُ وَبَدَأَ خَلْقَ الْإِنْسَانِ مِنْ طِينٍ

**«Ул һәр бар иткән нәрсәсен күркәм итте, кешене яралтуны юеш балчыктан башлады»** («әс-Сәҗдә», 7).

Юеш балчык этабында су катнаша. Су, беренче чиратта, чистарткыч ролен үти һәм пакьлек элементы булып тора. Бу яктан караганда, су кешедәге гыйффәтлекне, намусны һәм матди-рухи пакьлек хисләрен белдерә.

**3. Ябышкак юеш балчык этабы.**

إِنَّا خَلَقْنَاهُمْ مِنْ طِينٍ لَازِبٍ

**«…Һичшиксез, Без аларны** (Адәмне һәм аның нәселен) **үзле юеш балчыктан яралттык»** («әс-Саффат», 11).

Ябышкаклык, берегү кешенең тугрылык, бәйлелек хисен күрсәтә. Кешенең үҗәтләнүе, үзе яклаган фикерләрендә аяк терәп каршы торуы – бу этапның бер нәтиҗәсе.

**4. Һавада кипкән дымлы балчык этабы.**

وَلَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنْسَانَ مِنْ صَلْصَالٍ مِنْ حَمَإٍ مَسْنُونٍ

**«Һичшиксез, без кешене** (һавада) **кипкән дымлы балчыктан, бер рәвешкә кергән балчыктан яралттык»** («әл-Хиҗер», 26).

Әлеге аятьтә искә алынган «салсал – һавада кипкән дымлы балчык» этабында «һава» элементы өстәлә. Һава кеше ясала торган балчыкка хәрәкәтлелек үзлеге алып килә. Адәм баласы холкындагы тотрыксызлык, үз фикереннән кайту, сүздә тормау һәм җимерүгә хирыслык сыйфатлары шушы этап нәтиҗәсендә пәйда була.

**5. Бер рәвешкә кергән балчык этабы.**

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي خَالِقٌ بَشَرًا مِنْ صَلْصَالٍ مِنْ حَمَإٍ مَسْنُونٍ

**«Менә Раббың фәрештәләргә әйтте: “Һичшиксез, мин** (һавада) **корыган үзле, бер рәвешкә кергән балчыктан кеше яралтачакмын”»** («әл-Хиҗер», 28).

«Хамә-и мәснүн – бер рәвешкә кергән балчык» этабы кешенең билгеле бер рәвешкә керү, тәрбияләнә, укытыла-өйрәтелә алу кебек үзенчәлекләренә ишарәли. Аның бу сыйфатының яхшы ниятtә дә, начарга да файдалану мөмкинлеге бар. Иң мөһиме – бәндәгә дөрес юнәлеш бирә белү.

**6. Утта яндырылган балчык этабы.**

خَلَقَ الْإِنْسَانَ مِنْ صَلْصَالٍ كَالْفَخَّارِ

**«Аллаһ кешене утта яндырылган кебек чыңлап торган бер балчыктан яралтты»** («әр-Рахман», 14).

Бу этапта процесска ут кушыла. Кешенең тәкәбберлек, горурлык, көнчелек, Аллаһ әмерләренә каршы килү, ялган сөйләү шикелле сыйфатлары уттан башлангыч ала.

«Мүэминүн» сүрәсенең 12–14 нче аятьләре Хәзрәти Адәмнән соң аның нәселеннән киләчәк һәр кешене яралту тәртибен түбәндәгечә бәян кыла:

وَلَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنْسَانَ مِنْ سُلَالَةٍ مِنْ طِينٍ. ثُمَّ جَعَلْنَاهُ نُطْفَةً فِي قَرَارٍ مَكِينٍ. ثُمَّ خَلَقْنَا النُّطْفَةَ عَلَقَةً فَخَلَقْنَا الْعَلَقَةَ مُضْغَةً فَخَلَقْنَا الْمُضْغَةَ عِظَامًا فَكَسَوْنَا الْعِظَامَ لَحْمًا ثُمَّ أَنْشَأْنَاهُ خَلْقًا آخَرَ فَتَبَارَكَ اللَّهُ أَحْسَنُ الْخَالِقِينَ

**«Һичшиксез, Без кешене саф** (сөзеп чыгарылган) **балчыктан яралттык. Шуннан соң аны ышанычлы бер урын эчендә** (аналыкта) **тамчы иттек. Шуннан соң ул тамчыны оешкан канга** (ябышкан һәм аталанган йомыркага) **әверелдердек. Аннары ул оешкан канны мудга**[30] (бер чәйнәлгән ит) **хәленә китердек, ул чәйнәлгән ит кисәген сөякләргә** (скелетка) **әверелдердек, шуннан соң ул сөякләргә ит кундырдык. Шуннан соң аны башка бер яралтылыш белән** (кеше буларак) **бар иттек. Яралтучының иң күркәме**[31] **булган Аллаһ»** («әл-Мүэминүн», 12–14).

Медицина фәне бу мәгълүматларга бары безнең гасырда гына ирешә алды. Коръәни-Кәримдә исә Җәнабел-Хак кешенең яралгы үсеше этаплары турында 1400 ел чамасы элек үк фәнни дөреслеккә туры килгән рәвештә хәбәр иткән.

Югарыдагы аяти кәримәләрдә Җәнабел-Хак кешенең бик гыйбрәтле, игътибарга лаек яралтылу этаплары турында сөйли. Бу этапларның әүвәлгерәге булган балчык, ягъни Хәзрәти Адәм яралтылган туфрак этабының күренеш ягыннан бернинди кыйммәте дә, матурлыгы да юк. Шуннан соңгы этаплар исә – бер урынга атылган су тамчысы, авызда чәйнәлгәндәй рәвештәге оешкан ит кисәге бер дә матур күренеш булмаган, хәтта җирәнү хисе тудырган нәрсә... Аннары илаһи кодрәт күренеше буларак, күркәмлек, матурлык манзарасына ия сәнгать әсәренә тиң кешенең барлыкка килүе... Соңыннан исә матдә белән рухның куәтлелеге һәм ныклыгы, ахыр чиктә бәндә әлеге үсеш сәфәренең янә беренче этабына таба кайтып, кабат туфракка әләгә һәм шунда череп югала!.. Аннары исә черегән тән эчендә терекөмеш тамчысы шикелле, черемәгән һәм үзенә «асбуз-зәйнәб» дип аталган бердәнбер орлыктан, берәр үсемлекнең үсеп, өлгерү процессы тизәйтелгәндәй, кабат барлыкка килә һәм җанланып аякка баса!..

30. Мудга, бер чәйнәлгән ит – аяти-кәримәдәге бу тәгъбир без яшәгән гасырда гына ачылган Коръән могҗизасы булып тора. Кешене яралтуның өченче этабын тәшкил иткән мудга этабында яралгы тешләп кабылган һәм өстендә теш эзләре калган ит кисәген хәтерләтә..

31. Карагыз: 21 нче сылтама, 61 б.

Җәнабел-Хак бик күп аяти кәримәдә кешене бу муллык дөньясындагы маҗарасы турында фикерләргә, уйларга чакыра:

وَمَنْ نُعَمِّرْهُ نُنَكِّسْهُ فِي الْخَلْقِ أَفَلَا يَعْقِلُونَ

**«Без кемгәдер озын гомер бирсәк, аның яралтылышта** (көч-куәтен алып) **киресен әйләндерәбез. Әллә алар** (бу күренешне) **аңламыйлармы?** (Әлеге гыйбрәтле сәфәрне төшенә алмыйлармы)**»** («Йәсин», 68).

اَللّٰهُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ ضَعْفٍ ثُمَّ جَعَلَ مِنْ بَعْدِ ضَعْفٍ قُوَّةً ثُمَّ
جَعَلَ مِنْ بَعْدِ قُوَّةٍ ضَعْفًا وَشَيْبَةً يَخْلُقُ مَا يَشَاءُ وَهُوَ الْعَلِيمُ الْقَدِيرُ

**«Аллаһ сезне бер зәгыйфьлектән яралтты, шуннан соң зәгыйфьлек артыннан куәт бирде, шуннан соң куәт артыннан көчсезлек һәм картлык бирде. Ул теләгәнен кыла. Ул – Белүче, Кодрәт иясе»** («әр-Рум», 54).

مِنْهَا خَلَقْنَاكُمْ وَفِيهَا نُعِيدُكُمْ وَمِنْهَا نُخْرِجُكُمْ تَارَةً أُخْرَى

**«Без сезне аңардан** (туфрактан) **яралттык, янә сезне аңа кайтарачакбыз, тагын бер мәртәбә сезне аңардан чыгарачакбыз!»** («Та-һә», 55).

Бу хакыйкать шуны күрсәтә: кешенең тәне дөньядә кичергән этаплары һәм үзенең шәхси хәл-әхвәле белән фанилыкка мәҗбүр ителгән. Ә мөһиме һәм мәңгелеге – җан. Җәннәт-җәһәннәмгә бәхет яки газап юлы нәкъ менә җан белән үтеләчәк. Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ мондый нәсыйхәт бирә:

«Бәдәнеңә майлы-баллы нәрсәләрне азрак бир, чөнки тәнеңне тукландырган нәрсә нәфес теләкләренә батыра һәм ахырда оятка калдырып китә».

«Җанга рухи азыклар бир. Өлгергән уй-фикерләр, читнең хәлен аңлый белү һәм рухи ризыклар тәкъдим ит. Барасы җиренә – мәңгелек галәмгә көчле булып китсен!»

**Җан кертелү (өрелү)**

Җәнабел-Хак кешене бер уч туфрактан бар кылганнан соң, аңа мәхлуклар арасында иң югары дәрәҗә биреп, үзеннән бер сер, яшерен нәрсә өрә. Бер җисем рәвешендә яралтылган кешедә терелек үзенчәлеге бары җан өрелгәч кенә пәйда була. Бу күзлектән караганда, җан өрелү – барыннан да бигрәк, Аллаһның үз колын кадерләве һәм аңа җанлылык бирүе дигән сүз. Аллаһ Тәгалә әлеге хакыйкатьне:

فَإِذَا سَوَّيْتُهُ وَنَفَخْتُ فِيهِ مِنْ رُوحِي

**«Мин аны төзек бер хәлгә китергәч һәм рухымнан аның эченә өргәч…»** («әл-Хиҗер», 29) аяте кәримәсендә бәян кыла.

Аллаһ Тәгаләнең Адәм галәйһиссәләмгә үз рухыннан өреп кертүе – күчерелмә мәгънәдәге гыйбарә. Бу бик зур хикмәтне әле зиһене, аң дәрәҗәсе түбән балага аңлатканда гадиләштереп сөйләүгә тиң һәм Җәнабел-Хакның үзендәге кайбер үзенчәлекләрне колына аның сәләте һәм аң дәрәҗәсе нисбәтендә ирештерүе дигәнне белдерә. Кеше үзенә өрелгән җан белән бергә Раббысыннан алган әманәтнең бәрәкәтен, кодрәтен һәм, гомумән, Раббысын таный, Аңа кол була. Адәм баласы илаһи серләр һәм илаһи бөеклекне үз сәләт-мөмкинлекләре кысаларында аңлый, кабул итә. Илаһи бөеклекнең кабул ителү үзәге – йөрәктә. Бу очракта йөрәк бәдән әгъзасын, матди нәрсәне түгел, хис-тойгы үзәге булган рухи урын мәгънәсен белдерә.

Җанга хуҗа булу кешегә төп өч вазифаны йөкли һәм бу вазифаларны башкару мәсьәләсендә Аллаһ аны тиешле аң-сәләт белән дә тәэмин итә:

1. Нәфесен тану: үз шәхесен һәм хикмәтен белү;
2. Үзенең яратылуыңны белү: Раббыны тану (мәгърифәтуллаһ);
3. Яралтучың каршында үзеңнең мескенлегеңне, мохтаҗлыгыңны белү.

Шуңа күрә бер әсәрдә:

مَنْ عَرَفَ نَفْسَهُ فَقَدْ عَرَفَ رَبَّهُ

*«Кем үзен таныса, Раббысын да таныр!»* – диелә (Аҗлуни, «Кәшфүл-Хафа, II, 361).

❁

Яралтылган тәүге нәрсә Мөхәммәд нуры булган кебек, җаннар яралтылганда да, Аның рухы беренчел. Башка җаннар, Аллаһның рух-шәрифенең кадер-хөрмәте беленсен, танылсын өчен, җәүһәрнең савыты, тышлыгы шикелле. Шуңа күрә Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне «Әбүл-Әрвах – Рухларның атасы» дип атыйлар.

Әбү Һурайра радыйаллаһу ганһе риваять кыла:

Әсхабе кирам Аллаһ Рәсүленә:

«Сиңа пәйгамбәрлек кайчан насыйп кылынды?» – дип сорау бирә.

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Адәм әле рух белән җәсәд арасында чакта...»* – дип җавап бирә (Тирмизи, «Мәнакыйб», 1).

Шунлыктан Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәрлектә дә беренче булып тора. Аның вөҗүде, рухы һәм пәйгамбәрлеге иң беренче булудагы хикмәт турында фәрештәләрне Хәзрәти Адәмгә сәҗдә кылырга мәҗбүр итү бүлекчәсендә аңлатып үтәрбез.

Җанны ике дәрәҗәгә аерып карый алабыз:

1. **Солтани рух** (югары дәрәҗәле җан) – әмер галәменнән. Асылда, тәннән аерым. Тән белән кушылуы бу тәнне файдаланып тору рәвешендә чынга аша. Гәүдәнең череп юкка чыгуы җанга йогынты ясамый. Ләкин ул очракта бу гәүдәне бәдәни теләкләрне тормышка ашыру өчен кулланып торуы тәмамлана.

2. **Хайвани рух** (хайван җаны) – бар ителгән (халикъ) галәмнән. Тәннең бөтен очлыкларына таралган. Төп идарәсе кан аркылы башкарыла. Үзәге – баш мие. Гамәлләрнең, эш-хәрәкәтләрнең башлангыч ноктасы булып тора. Әгәр хайвани рух булмаса, һичбер тән-гәүдә тере булып яши алмас иде.[32]

Кешенең эш-гамәлләре солтани рух белән хайвани рухның уртак, гомуми холык-фигыле аша чынга ашар.

**Җанның биш чоры**

**1. Юклык чоры.**

Мәңгелек бары тик Җәнабел-Хакка гына хас һәм Аннан кала һичкем булмый. Ул чорда җаннар да юклык эчендә була. Аяти кәримәдә бу хакта:

هَلْ أَتَى عَلَى الْإِنْسَانِ حِينٌ مِنَ الدَّهْرِ لَمْ يَكُنْ شَيْئًا مَذْكُورًا

**«Кешенең искә алынмый торган бернәрсә булган чагы үтмәдемени?»** – диелә («әл-Инсан», 1).

**2. Җаннар галәменең барлыкка килү чоры.**

Аллаһ Тәгалә бик күп хикмәткә нигез итеп, бәдәннәрне яралтканчы, әүвәл җаннарны бар кылды. Хәдис-шәрифтә бу хәл хакында:

*«Җаннар бәдәннәрдән ике мең ел элегрәк яралтылган!»* – диелә (Дәйләми, «Муснәд», II, 187–188).

**3. Кеше тәненә кертелү чоры.**

Тәннәрдән шактый элегрәк яралтылган һәм үзләреннән Аллаһның бирелгән һәм барлыгын тануда ант бирдертелгән җаннар, мәңгелектә язып куелган язмыш планына ярашлы рәвештә, берәм-берәм бәдәннәргә җибәрелә башлый.

32. Карагыз: И. Хакки Бурсәви, «Тәмамүл-Фәйз» (Али Намлы шәрехләре белән), басылып чыкмаган диссертация аннотациясе, Истанбул, 1994, 47 б.

Аяти кәримәдә беренче кеше – Хәзрәти Адәмгә җан өрелү турында болай диелә:

وَنَفَخْتُ فِيهِ مِنْ رُوحِي

**«…Аңа рухымнан (җан) өргәч...»** («әл-Хиҗер», 29).

**4. Тәннән аерылу чоры.**

Бу фани тормышта үзенә бирелгән гомерне тәмамлагач, җаннар билгеле бер вакыт аралыгында бергә булган тәннәрдән берәм-берәм китеп тә бара. Һичкем качып котылып кала алмаслык бу хәл үлем дип атала. Аяти кәримәдә:

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ

**«Һәр җан үлемне татыячак!..»** – дип белдерелә («Әли Гыймран», 185).

**5. Кабат тәннәргә кайтарылу чоры.**

Ислам гакыйдәсенә күрә, үлем ул юкка чыгу түгел, ә ана карынындагы бала, андагы бәйләнешне өзеп, дөньяга килгән кебек, җанның бу фани галәмнән котылып, мәңгелек тормышка аяк басуы. Монда Адәм баласы дөньяда яшәгән тормышы өчен хисап тотачак. Шуның нәтиҗәсенә бәйле рәвештә, чиксез бәхеткә ирешәчәк яки (Аллаһ сакласын) мәңгелек газапка дучар ителәчәк. Әлеге мәсьәләгә мөнәсәбәтле йөзләрчә аятьтән икесе мондый:

قُلْ يُحْيِيهَا الَّذِي أَنْشَأَهَا أَوَّلَ مَرَّةٍ وَهُوَ بِكُلِّ خَلْقٍ عَلِيمٌ

**«Әйт: “Аларны беренче мәртәбә** Яралтучы (Аллаһ янә аларны шул ук шәкелдә) **терелтәчәк. Ул бит һәр яралтылган нәрсәне белүче”»** («Йәсин», 79).

«Тәквир» сүрәсендә куркыныч һәм гыйбрәтле кыямәт галәмәтләренең аерымлыклары турында сөйләгәндә, Җәнабел-Хак җаннарның яңадан тән калыбына кертелүен болай дип телгә ала?

وَإِذَا النُّفُوسُ زُوِّجَتْ

**«Җаннар берләштерелгән** (җаннар бәдәннәр белән бер урынга китерелгән) **вакытта»** («әт-Тәквир», 7).

❀

Кешегә Раббысыннан бер сер буларак өреп кертелгән җанның асылын тулысынча аңлап-белеп бетерү мөмкин түгел, чөнки ул – метафизик галәмгә хас нәрсә һәм кеше аңы җитмәслек асыл сыйфатларга ия. Хактан да, җанның мондый үзенчәлеге турында аяти кәримәдә анык белдерелә:

وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الرُّوحِ قُلِ الرُّوحُ مِنْ أَمْرِ رَبِّي وَمَا أُوتِيتُمْ مِنَ الْعِلْمِ إِلَّا قَلِيلًا

**«Алар синнән рух хакында сорыйлар. Әйт: “Рух – Раббымның әмереннән. Сезгә исә гыйлемнән аз бер өлеш кенә бирелде”»** («әл-Исра», 85).

Җанның Аллаһ Тәгалә белән бәйләнеше мәсьәләсендә мөфәссирләр берничә төрле аңлатма бирә:

– Җан – бары Раббыбызга гына билге булган нәрсә.

– Җан – «әмер»нең нигезе булган асыл җәүһәр ул.

– Җан – Раббыбызның әмер төреннән бер гамәл ул.

Аятьтән телгә алынган «әмер» сүзе, шул ук тамырдагы «әмарәт» сүзе белән бәйләнештә каралганда, фәрман бирү, боеру, идарә итү мәгънәсендә шәрехләнә ала. Андый очракта җан әмернең рәвеше һәм сыйфаты дигән сүз булыр. Бу исә Аллаһ сыйфатларының колда чагылыш табуын белдерә, ягъни илаһи сыйфатларның берсе – әмарәт (идарә итү) колда да барлыкка килә. Әйтик, кешенең «Аллаһ хәлифе» булуы аңарга идарә итү сыйфаты бирелү белән дә бәйле.

Идарә итә белү кешегә бирелгән олуг дәрәҗә санала. Арыслан гәүдәсенең кешенекеннән шактый көчлерәк булуына карамастан, бәндәнең камиллеге алдында мескенләнеп, зәгыйфьләнеп кала. Әйтик, мең ел яшәсә дә, арыслан үзенә бер йорт та төзи, берәр корал да ясый алмый.

Шулай ук фәрештәләрдә дә тулы мәгънәсендә андый сыйфат күренми. Бу төр сәләт бары тик кешегә бирелгән. Адәм баласы «ахсәни тәквим – иң күркәм дәрәҗә» белән «бәл һүм әдалл – хайваннардан да түбәнрәк баскыч» арасында урын ала. Әйтик, кешенең йөрәгендә чагылыш тапкан «Рахман» һәм «Рәхим» сыйфатлары белән бергә, аның нәфесендә «Музилл» (юлдан яздыручы) һәм «Кибрия» (тәкәбберлек) сыйфатлары да чагылыш таба. Димәк, кеше җәмигуль-әздад булып тора, ягъни ул барлык уңай һәм тискәре сыйфатларны үзендә туплаган. Җәмигуль-әздад дигән бәяләмә мәхлуклар арасында тулы мәгънәсендә бары кешегә генә хас.

Югарыда искә алынган аяти кәримәнең ахырында кешегә җанның сыйфатлары турында бик аз мәгълүмат бирелгәнлеге анык белдерелә. Димәк, кеше, үзенә билгеләнгән чикләрне узып, җанга бәйле серләрне ачарга маташу белән шөгыйльләнмәскә, бу хакта белемнәре белән мактанмаска, горурланмаска, аның урынына үзенә йөкләнгән бурыч-вазифалар турында фикерләп, гыйбадәтенә әһәмият бирергә тиеш.

Җәнабел-Хак, Адәм галәйһиссәләмне яралтканнан соң, фәрештәләрнең кешегә көнләшерлек һәм тәкъдирендә Аллаһның әмеренә буйсынырлык

дәрәҗәгә ирештерү өчен, аңа әйберләрнең исемнәрен өйрәтә. Аяти кәримәдә бу вакыйга түбәндәгечә бәян кылына:

وَعَلَّمَ آدَمَ الْأَسْمَاءَ كُلَّهَا ثُمَّ عَرَضَهُمْ عَلَى الْمَلَائِكَةِ فَقَالَ أَنْبِئُونِي بِأَسْمَاءِ هَؤُلَاءِ إِنْ كُنْتُمْ صَادِقِينَ

**«Аллаһ исемнәрнең барчасын Адәмгә өйрәтте, шуннан аларны фәрештәләргә күрсәтеп: “Әгәр сез хаклы булсагыз** (һәрнәрсәнең эчке ягын беләм, дип санасагыз)**, минә бу нәрсәләрнең исемнәрен Миңа әйтегез!” – диде»** («әл-Бәкара», 31).

Фәрештәләр Аллаһны тәсбих кылды һәм Аның бөеклеген, пакьлеген раслады. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә:

قَالَ يَا آدَمُ أَنْبِئْهُمْ بِأَسْمَآئِهِمْ فَلَمَّا أَنْبَأَهُمْ بِأَسْمَآئِهِمْ قَالَ أَلَمْ أَقُلْ لَكُمْ إِنِّي أَعْلَمُ غَيْبَ السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ وَأَعْلَمُ مَا تُبْدُونَ وَمَا كُنْتُمْ تَكْتُمُونَ

**«И, Адәм, аларга** (шул нәрсәләрнең) **исемнәрен әйтеп бир!» – диде. Ул** (әйберләрнең) **аларга исемнәрен әйтеп биргәч,** (Җәнабел-Хак)**: «Мин сезгә: “Күкләрдәге вә җирдәге гаиб нәрсәләрне беләмен һәм сезнең ачык эшләгән вә яшерен эшләгән эшләрегезне дә беләмен, дип әйтмәдеммени?” – дип әйтте»** («әл-Бәкара», 33).

Хәзрәти Адәмгә өйрәтелгән исемнәрнең чынлыкта ни булганлыгы мәсьәләсендә мөфәссирләрнең берничә төрле фикере бар:

1. Әлеге исемнәр кешеләрнең танышу-аралашуына, үзара аңлашуына китергән барлык исемнәр турында сүз бара. Мәсәлән, кеше, хайван, җир, диңгез, тау, карга, күгәрчен кебек атамалар. Ягъни бөтен телләрнең асылын тәшкил иткән сүзләрнең барысы да аңа өйрәтелә. Кыяматкәчә булган, булачак бөтен нәрсәләрнең исемнәрен шулвакытта ук өйрәтеп куелган, дип фикер йөртүчеләр дә билгеле.

2. Фәрештәләрнең исемнәре.

3. Хәзрәти Адәм нәсел-нәсәбенең исемнәре.

4. Исемнәр өйрәтүдә максат тел түгел, ә әйберләрнең үзенчәлекләрен күрсәтү. Башкача әйткәндә, шул үзенчәлекләрдән гыйбарәт сурәтләре күз уңында тотыла.

Әгәр исемнәр җан өрелгәнче өйрәтелгән булса, бу Хәзрәти Адәмгә сөйләшү сәләте һәм барлык нәрсәләргә исем бирү мөмкинлеге бүләк итеп җибәрелгән, дигәнне аңлатыр иде. Нәтиҗәдә, Хәзрәти Адәм Аллаһ кушкан тәкъдир нигезендә бөтен мәхлукларга бер-бер артлы исем бирүче булыр иде.

Исемнәр җан өрелгәндә яки шуннан соң өйрәтелсә, ул очракта һәрнәрсәгә исем бирүче Аллаһ Тәгалә икәнлеге раслана. Исемнәр соңрак Хәзрәти Адәмгә илһам җибәрү яки гыйльми зарурлык тудыру ысулы белән берәм-берәм өйрәтелә.

Югарыда искә алынган беренче карашка күрә, «барлык исемнәр», дигәндә, кыяматкача бөтен телләрдәге исемнәр күздә тотыла. Икенче карашка ярашлы рәвештә, сүз иң әүвәл кулланышта булган барлык исемнәр турында бара.

Мөфәссирләр «исемнәр өйрәтелү» гыйбарәсен әнә шулай ике төрле аңлата.

Хәзрәти Адәмгә исемнәрне өйрәткәннән соң, күпмедер вакыт узгач, Аллаһ Тәгалә бу исемнәр белдергән, ягъни аларның барлыгын раслаган мәхлуклар турында фәрештәләрдән сорый. Монда иң өстә яткан мәгънә әлеге исем бирелгән нәрсәләрнең Хәзрәти Адәмгә буйсыначак, иярәчәк нәсел-нәсәп турында булуында. Бер үк вакытта барлык исемнәрнең өйрәтелеп тә, фәрештәләргә шул нәсел-нәсәпкә кагылышлыларының гына ачып бирелүе дә ихтимал (Карагыз: Әлмалылы, I, 287–290).

Бу фикерләрнең барысын да бергә берләштергән карашка күрә, Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмгә исемнәр өйрәтүнең максаты җир йөзендәге барлык әйберләрнең исемнәрен, сыйфатларын һәм үзенчәлекләрен ачып бирүдән гыйбарәт. Монда без белмәгән илаһи сәнгать, әйберләрнең эчтәлеге, яратылу сере, ләүхел-мәхфүз, язмыш һәм андагы хикмәтләр белән күк һәм җирдәге барлык илаһи серләр, ягъни илаһи исем-сыйфатларның чагылышы.[33] Димәк, Җәнабел-Хакның танылуы-беленүе бары тик йөрәк белән тоеп яшәгәндә генә мөмкин. Әйберләрнең эчтәлеге һәм серләре йөрәк белән тоюга нисбәтле рәвештә ачыла. Бу исә илаһи исем-сыйфатларны аңлау, тануга бәйле. Җәнабел-Хак:

وَ لِلّٰهِ الْأَسْمَاءُ الْحُسْنَى

**«Иң күркәм исемнәр – Аллаһныкы...»** – дип («әл-Әгъраф», 180), илаһи исемнәре аша үзен колларының аң-зиһененә тәкъдим итә, чөнки кол илаһи элемтәне исем ярдәмендә урнаштыра. Әлеге хакыйкать Аллаһның исеме Аны зурлар өчен кирәкле, һич кире кагып булмый торган элемент икәнен раслый. Бу күзлектән караганда, колның Хак Тәгаләгә каршы кылган игелекле һәм начар гамәлләре Аллаһның асылына түгел, ә исеменә юнәлтелер. Шул рәвешле илаһи хакыйкать һәрвакыт саф, пакь калыр.

Чыннан да кеше, әгәр Җәнабел-Хакка хас исемнәр булмаса, Аның белән элемтә урнаштыруда читенлек тояр, чөнки адәм баласы теге яки бу нәрсәне исеме белән кабул итәргә, исеме белән дәшәргә күнеккән. Кеше өчен теге яки бу нәрсәнең исеме ул нәрсәнең барлыгын билгели, дәлилли. Шуңа күрә дә

33. Киңрәк мәгълүмат алу өчен карагыз, «Имандан ихсана тасаввуф», 309 б. һ.б.

Җәнабел-Хак, Адәм галәйһиссәләмне яралткан вакытта, аңа бөтен исемнәрне өйрәтә һәм шуның белән Хәзрәти Адәмнең фәрештәләрдән өстенлеген белдерә. Чөнки бер мәхлукның исемен белү – аның барлыгын да тану дигән сүз. Без Җәнабел-Хакны бөек исемнәре аша белмәсәк, Аның турында нәрсә белә алыр идек икән?

Димәк, кеше Раббының сыйфатларын белдергән исемнәргә һәрдаим мохтаҗ. Һәр кол үзе тарыган, кичергән төрле хәлләрдә Раббысына шул хәленә туры килгән исеме белән дәшәргә тели. Бу исемнәр булмаса, Аның белән элемтәсе, мөнәсәбәте бик җайсызланыр, чикләнер иде, хәтта мөмкин дә булмас иде. Әлеге исемнәрне Бөек Аллаһ каршында колның телсезлеген билгеле бер дәрәҗәдә бетергән гыйбарәләр, ягъни бәндә җанының чишелеш проблемаларына юл ача торган ачкычлар дип атарга була. Чөнки Аллаһның исемнәрен хәтта зикер итеп искә алу да иманны тукландыра, Хак каршындагы хозурлыкны тоярга юл ача, Аңа карата мәхәббәтне арттыра, Аңа карата хошуглык иясенә әйләндерә, Аның катында булучыларга таба омтылыш тудыра, дөньядан һәм аның фани ләззәт һәм рәхәтлекләреннән баш тартып, мәңгелеккә юнәлтә, Хак Тәгаләгә кайту, Аның белән күрешү теләгенә ирештерә. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм төрле хәл-әхвәлләрдә укырга киңәш иткән дога-зикерләрдә Аллаһның исемнәре күпләп телгә алыну да бу исемнәрнең фазыйләтеннән файдалануны тәэмин итә.

Бик авыр шартларда яшәгән, илаһи мәрхәмәткә бик мохтаҗ бер мөэмин зат, Раббысыннан ярдәм сораганда, мондый хәлен кыска гына аңлатып бирә торган берәр сүз эзләп, «Рахман вә Рәхим» исемнәренә сыеныр. Гөнаһларының авырлыгы астында изелгәндә, күңел кылларының тартылып өзелгәнен тойганда, Хак Тәгаләгә якынайтырлык бер нигез эзләп, «Гаффар һәм Саттар» исемнәренә сыеныр. Табигатьтә яки үз җанында ачылган илаһи кодрәт һәм бөеклекне күргәч, китапларда тасвирлап бирә алмаслык хис-тойгысын һәм осталыгын аңлатып бирерлек гыйбарә эзләгәндә, «Аллаһу әкбәр» дип, дулкынланган җанын тынычлыкка ирештерер. Кыскасы, кол үз тормышындагы төрле хәлләрдә, Җәнабел-Хакның төрле исем-сыйфатлары ярдәме белән, күңеленең бикле ишекләрен ачар һәм күпме борчу-мәшәкатьләрен, ихтыяҗларын бетерер.

Шуңа күрә Җәнабел-Хак, хакыйкатькә ярашлы рәвештә, үзен кешеләр генә аңлый алырлык формада таныта, ягъни Аның үз-үзен Галим, Хаким, Кадир, Гафур һ.б. сыйфатлар аша танытуында һәм бәндәнең дә Аны шул рәвешле тануында, асылда, кешегә бәйле шәхси сәбәп бар. Чөнки кеше бу сыйфатларның бер өлешен, бик чикле дәрәҗәдә булса да, үзендә таба. Бу да – бәндә аңының иман һәм һидәяте өчен насыйп ителгән бер илаһи бүләк.

Җәнабел-Хак Адәм галәйһиссәләмгә исемнәрне өйрәтүе турында белдергән аяти кәримәдә шулай ук: «Мин әйберләрнең исемнәрен, серләрен, хикмәт-

ләрен, матурлыкларын һәм илаһи сәнгатемне кешегә белгертәчәкмен…» – дигән мәгънәне дә иңдерә.

Монда кешенең фазыйләт һәм шәрәфкә ул алачак файдалы белем бәрабәренә ирешү мөмкинлегенә ишарәт кылына. Шуңа күрә кеше, гыйлемен гыйрфанга әйләндереп, изге гамәлләр кылырга тырышырга тиеш, чөнки тәкъвалык – төп максат булып тора. Җәнабел-Хак аяти кәримәдә:

إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِنْدَ اللّٰهِ أَتْقٰيكُمْ

**«…Аллаһ хозурында иң кадерлегез – бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз…»** – дип белдерә («әл-Хуҗурат», 13).

Акыл – Аллаһ яралткан мәхлук ул. Акыл Аллаһны дәлилләп тану аша исбатлый ала, чөнки ул әсәр аша аны бар итүчене, сәнгать аша сәнгатькярне таный. Хикмәтне исә бары вәхи яктысында гына төшенә ала. Ләкин акылның вәхи эчтәлеген аңлауда да сәләте һәм көч-куәте чикле. Аллаһны тану юлында акыл белән алга барып булса да, бу юл билгеле бер урынга кадәр генә илтәчәк. Акыл көче төкәнгән җирдә күңел белән башкарылган гамәлләр бәрабәренә алга барып булачак. Ләкин хәтта бу да чынбарлыкка һичшиксез барып җитү өчен җитәрлек түгел, чөнки Аллаһның бөеклеге мәҗбүри. Мәҗбүрилекнең капма-каршысы – мотлак булмаган акыл яки башка бер чара ярдәмендә бөеклекне төшенеп бетерү һәм аны лаеклы дәрәҗәдә төшенә алу мөмкин түгел.

Аяти кәримәдә:

وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلَّا بِمَا شَاءَ

**«...Ул теләгән нәрсәләрдән тыш, алар Аның гыйлеменнән берни дә төшенә алмый…»** – дип анык әйтелә («әл-Бәкара», 255).

Шуңа карамастан, кеше Аллаһны тану юлыннан баш тартырга түгел, ул Раббысына якынаю өчен җай, сәбәп эзләргә һәм моңа бар көчен салырга тиеш. Бу юлда тырышлыкның иң күркәм үрнәген пәйгамбәрләрдә күрергә мөмкин. Әйтик, Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм:

وَقَالَ إِنِّي ذَاهِبٌ إِلَى رَبِّي سَيَهْدِينِ

**«Мин Раббыма китәмен. Һичшиксез, Ул миңа хак юлны күрсәтәчәк»**, – дип әйтә («әс-Саффат», 99).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә:

*«Я Раббы! Без Сине Сиңа лаек мәгърифәт[34] белән таный алмадык...»* – дип (Мөнави, «Фәйзүл-Кадир», II, 520), мәгърифәтнең, ягъни Аллаһ Тәгаләне тиешле

34. Мәгърифәт – Аллаһны ихлас тану дигән сүз.

дәрәҗәдә таный алуның мөмкин түгеллегенә һәм шул ук вакытта моның әһәмиятенә һәм кирәклегенә ишарәли.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Җәнабел-Хактан өч төрле гыйлем ала:

Беренче: Үзе белән Аллаһ Җәллә Җәләлүһү арасында саклана. Бу гыйлем бәндә аңы җитә алмаслык булганга, ул кешеләргә аңлатылмый. Аңа бары тик пәйгамбәрлек нуры белән генә төшенеп була. Кайбер сүрәләр башындагы «хуруфи мукаттага» белдергән мәгънәләр – шушы исәптән. Мәсәлән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, тәблигъ эшенә таләп ителгән вәхидән кала, үзенә шәхсән иңдерелгән һәр мәгълүматны да сәхабәләренә тапшырып бармаган. Рәсүлүллаһ Әфәндебезнең бу хәдис-шәрифе әнә шул хикмәткә ишарәли:

*«Әгәр мин белгәннәрне белсәгез, аз көләр, күп елар идегез»* (Бохари, «Күсуф», 2; Мөслим, «Саләт», 112).

Әлеге мәсьәлә белән бәйле башка бер хәдис-шәрифтә дә:

*«Минем Җәнабел-Хак белән элемтәмдә шундый мизгелләрем була ки, аларга һичбер фәрештә якын килмәс, бер пәйгамбәр дә хәбәрдар булмас»*, – дип әйтелә (Мөнави, «Фәйзүл-Кадир», IV, 8).

Икенче: гавамга караган шәригать гыйлеме. Бөтен кешелек дөньясы бу гыйлемнәргә иман китерергә һәм алар белән гамәл кылырга бурычлы. Түбәндәге аяти кәримәдә шундый гыйлем телгә алына:

يَا أَيُّهَا الرَّسُولُ بَلِّغْ مَا أُنْزِلَ إِلَيْكَ مِنْ رَبِّكَ وَإِنْ لَمْ تَفْعَلْ فَمَا بَلَّغْتَ رِسَالَتَهُ

**«И, Рәсүл! Раббыңнан сиңа иңдерелгәнне ирештер. Әгәр моны эшләмәсәң, Аның рисаләтен җиткермәгән булырсың!..»** («әл-Маидә», 67).

Өченчесе: Билгеле бер төркемгә, лаеклы затларга, гыйлем ияләренә бирелә. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу гыйлемнең аны төшенмәгән, галим булмаган затларга бирелүен тыя. Бервакыт Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмәгә:

*«Әй Ибне Габбас, кешеләргә аларның акылы җитмәслек сүзләр сөйләмә, чөнки бу гамәлең араларында фетнә кубуга сәбәп булыр»*, – дип киңәш бирә (Дәйләми, «Муснәд», V, 359/8434). Шуңа күрә Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе:

*«Кешеләргә алар аңлаган нәрсәләрне сөйләгез, аңламаганнарын калдырыгыз. Сез Аллаһ һәм Аның Рәсүле ялган сөйли, дигән яла ягуларын телисезме?»* – дип әйткән (Бохари, «Гыйлем», 49).

Шулай ук Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмәдән килгән бер риваятькә күрә, сәхабәләр:

«Йә Аллаһның Рәсүле! Синнән ишеткәннәребезнең барысын да сөйләп бирикме?» – дип сорады. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Әйе. Ләкин кайбер җәмгыятькә акыллары җитмәслек нәрсәне аңлатуны исәпкә алмаганда, чөнки бу хәл кайберләренең фетнәгә чумуына китерер»*, – дип җавап бирде. Әлеге кисәтүдән соң Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмә ниндидер төркемгә берәр мәсьәләне аңлатканда, кайбер нәрсәләрне киная белән генә сөйли иде (Гали әл-Мүттакый, «Кәнзул-Уммал», X, 307/29537).

Бу мәсьәләдә Әбү Һүрайра радыйаллаһу ганһе болай ди:

«Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән ике савыт тулы гыйлем алдым. Боларның берсен халыкка аңлаттым. Әгәр икенчесен дә гавамга ачып бирсәм, муеныма чалырлар иде» (Бохари, Гыйлем, 42).

Сайлап алынган сәхабәләрнең зирәклеге, чикле затлардан яшергән мондый гыйлемнәре аңлау-төшенү ягыннан, гайре табигый сәләткә ия тиңсез кешеләр генә аңлый алырлык хикмәтләрдән гыйбарәт. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый хикмәтләрне сәхабәләреннән Хәзрәти Әбүбәкер һәм Хәзрәти Гали кебек кайбер искиткеч зирәк затларга тапшырган һәм белдергән. Гыйлемгә ирешү мәсьәләсендә һәркем үз сәләтеннән һәм кулыннан килгәнчә бурычлы. Кол үз бәхет-сәгадәте өчен андый сәләтен үстерергә, тәкъвалыкка, тыйнаклыкка, ихсанга омтылырга, башкача әйткәндә, гыйбадәтен иң күркәм рәвештә башкарырга тиеш. Моны исә бары нәфесне тәрбияләү һәм йөрәкне пакьләү юлы белән генә чынга ашырып була.

Бәндәнең бәхете беренче чиратта шәргый хөкемнәргә буйсыну белән бәйле. Ихлас гыйбадәтен тормыш чынбарлыгы белән берләштерү бу бәхетнең югары бер дәрәҗәдә, ягъни сыйфатлы рәвештә булуын тәэмин итә.

Шәргый хөкемнәр һәркемгә адресланганга күрә, илаһи рәхмәткә ирештерә торган бурыч-вазифалар иң аз дәрәҗәдә куела, гавамдагы иң мескен затларга хас сәләт, көч-хәл чикләре үлчәм итеп алына. Ихлас гыйбадәт юлында алга бару сәләткә, холык фигыльгә бәйле булганлыктан, бу юлның башы ачык калдырыла, Аллаһ үз әһеленә «Фәна филлаһ» (бар булмышыңны Аллаһка багышлау) һәм хәтта «Бәка билләһ» (һәрдаим Аллаһны искә алу халәте, фәна филлаһның югары дәрәҗәсе) кадәр гыйбадәттә булырга рөхсәт кыла.

Мәсәлән, бер өлеш малларда зәкят кырыктан бер өлеш тәшкил итә, шул ук вакытта Җәнабел-Хак юлында сарыф итүнең чиге билгеләнмәгән, мөэминнең, хәтта үзе турында уйламыйча, үзенә кирәк берәр нәрсәне мохтаҗ кардәшенә бирүе хуплана. Димәк, зәкятнең фикһи хисабы, күңел күзлегеннән караганда, иң түбән дәрәҗәдә санала. Йөрәк белән гыйбадәт дәрәҗәсе күтәрелгән саен, Аллаһ юлында сарыф итүнең күләмнәре дә артыр.

Бу күзлектән караганда, Аллаһны тану, аны зикер итү гыйлеме кешенең үз холык-табигатен рухи тәрбияләү нәтиҗәсендә «ләдүнни» гыйлемгә

әйләнә. Мондый гыйлемнең барлыгы Коръәни-Кәримнең бер төркем аяти кәримәләрендә телгә алынуы белән дәлилләнә. Аллаһ Тәгалә Үзеннән курыккан, шәхси теләк-ниятләрен илаһи ирадәгә буйсындыра белгән колларының йөрәкләренә аларның акыллары белән үлчәп булмаслык һәдияләр кертә. Әйтик, Бөек Раббыбыз мондый тәкъва колларына аерым бер гыйлем һәм хикмәтләр биргәнен Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә белдерә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنْ تَتَّقُوا اللَّهَ يَجْعَلْ لَكُمْ فُرْقَانًا وَيُكَفِّرْ عَنْكُمْ
سَيِّئَاتِكُمْ وَيَغْفِرْ لَكُمْ وَاللَّهُ ذُو الْفَضْلِ الْعَظِيمِ

**«И, иман китерүчеләр! Аллаһтан курыксагыз, Ул сезгә бер фуркан** (яхшы белән начарны аерачак бер гыйлем, аң, зирәклек) **яралтыр, сезнең начар эшләрегезне каплар һәм сезне ярлыкар. Һичшиксез, Аллаһ – олуг фазыл иясе»** («әл-Әнфәл», 29).

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَآمِنُوا بِرَسُولِهِ يُؤْتِكُمْ كِفْلَيْنِ مِنْ رَحْمَتِهِ
وَيَجْعَلْ لَكُمْ نُورًا تَمْشُونَ بِهِ وَيَغْفِرْ لَكُمْ وَاللَّهُ غَفُورٌ رَحِيمٌ

**«И, иман китерүчеләр! Аллаһтан куркыгыз һәм Аның Рәсүленә** (Хәзрәти Мөхәммәдкә) **иман итегез. Ул сезгә рәхмәтеннән ике кат насыйп кылыр, сезгә йөрергә нур бирер һәм сезне ярлыкар. Аллаһ – Гафур** (күп гафу итүче) **һәм Рәхим** (бик мәрхәмәт күрсәтүче)**»** («әл-Хәдид», 28).

Имам Газали һәм Абдулкадири Гәйлани кебек затлар әүвәл анык билгеле гыйлемнәрне иң югары дәрәҗәдә үзләштерә. Ләкин кайбер яшерен нечкәлекләргә һәм Аллаһка илтә торган хисси, нәфис һәм нәзакәтле юлга күңел күзләренең тирәнлеге бәрабәренә генә һәм бик соң гына ирешә алалар, шул рәвешле Хак Тәгаләнең дустына әвереләләр. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү гавамга ачмаган кайбер серләрне, андый шәхесләрнең хис-тойгы, иман тирәнлеген күздә тотып, аларга һәм шундый кайбер искиткеч холык-табигатьле башка затларга ирештерә. Югыйсә алар шундый күренекле дәрәҗәдәге шәхесләр була алмас иде.

**Фәрештәләрнең Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмгә сәҗдә кылуы**

Адәм галәйһиссәләмне яралтып, үз рухыннан җан өргәч һәм аңа исемнәрне өйрәткәч, Җәнабел-Хак фәрештәләрнең Хәзрәти Адәмгә сәҗдә кылуын теләде. Бу хәл аяти кәримәләрдә болай тасвирлана:

وَإِذْ قَالَ رَبُّكَ لِلْمَلَائِكَةِ إِنِّي خَالِقٌ بَشَرًا مِنْ صَلْصَالٍ مِنْ حَمَإٍ مَسْنُونٍ.
فَإِذَا سَوَّيْتُهُ وَنَفَخْتُ فِيهِ مِنْ رُوحِي فَقَعُوا لَهُ سَاجِدِينَ. فَسَجَدَ الْمَلَائِكَةُ

كُلُّهُمْ أَجْمَعُونَ. إِلَّا إِبْلِيسَ أَبَى أَنْ يَكُونَ مَعَ السَّاجِدِينَ. قَالَ يَا إِبْلِيسُ مَا لَكَ أَلَّا تَكُونَ مَعَ السَّاجِدِينَ. قَالَ لَمْ أَكُنْ لِأَسْجُدَ لِبَشَرٍ خَلَقْتَهُ مِنْ صَلْصَالٍ مِنْ حَمَإٍ مَسْنُونٍ

**«Менә Раббың фәрештәләргә әйтте: "Һичшиксез, мин коп-коры бер балчыктан, рәвеш биреп, кеше яралтачакмын. Мин аны төзек бер хәлгә китергәч һәм рухымнан аның эченә өргәч, сез аңа сәҗдә кылыгыз". Фәрештәләр бөтенесе сәҗдә кылдылар. Ләкин Иблис сәҗдә кылучылар белән бергә булудан баш тартты. Ул: "И, Иблис! Ни булды сиңа, нишләп сәҗдә кылучылар белән бер булмадың?" – диде. Ул исә: "Син коп-коры балчыктан рәвеш биреп яралткан бер бәндәгә сәҗдә кыла алмам", – диде»** («әл-Хиҗер», 28–33).

Коръәни-Кәримдә әлеге вакыйга сүз уңаеннан төрле җиде сүрәдә искә алына, бу исә аның мөһимлеген раслый. Монда бик әһәмиятле күрсәтмә бар: Иблис Аллаһ кушканга колак салмый, үзенең нәфес теләкләренә ияреп гамәл кыла. Үз мантыйгындагы үлчәмнәрне һәм үз акылы тарафыннан бирелгән бәяләмәне Аллаһның әмереннән өстен куя. Димәк, үз акылын, мантыйгын һәм ышануларын Аллаһның әмереннән өстен куйган очракта, кол да Иблис кылган хатага эләгә. Хәлбуки, аяти кәримәдә әлеге хатага каршы мондый илаһи кисәтү ясала:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تُقَدِّمُوا بَيْنَ يَدَيِ اللَّهِ وَرَسُولِهِ وَاتَّقُوا اللَّهَ

**«Әй иман китерүчеләр! Аллаһ һәм Аның Рәсүленең алдына чыкмагыз һәм Аллаһтан куркыгыз...»** («әл-Хуҗурат», 1).

Хак Тәгалә шайтаннан аның сәҗдәдән тыелу сәбәбен сорый:

قَالَ يَا إِبْلِيسُ مَا مَنَعَكَ أَنْ تَسْجُدَ لِمَا خَلَقْتُ بِيَدَيَّ

**«Әй Иблис, ике кулым белән яралткан кешегә сәҗдә кылудан сине нәрсә туктатты?»** («Сад», 75).

Бу аятьтә искә алынган «ике кул» Аллаһ Тәгаләнең кодрәтен белдерә. Әлеге гыйбарә шул ук вакытта Җәнабел-Хак тарафыннан кешегә бирелгән әһәмиятне дә күрсәтә. Әлеге сүзләрнең тагын бер мәгънәсен Мөхетдин ибне әл-Гәраби болай аңлата:

«Ике кул – Хак Тәгаләнең бөеклеге һәм юмартлыгының чагылышы ул. Кешенең тән төзелеше, нәфесе аның барлыкка китерелүе белән бәйле һәм бөеклек чагылышы булып тора; рухи һәм Хак Тәгалә тарафы исә – Аның юмартлык чагылышы. Кешедә бу ике исем берләшкән хәлдә. Иблистә исә

бары бөеклек чагылышы гына булганлыктан, ул юмартлык сыйфатыннан өлеш алудан мәхрүм».

Хәдис-шәрифтә әйтелә:

*«(Һәртөрле сурәт һәм рәвештән азат) Аллаһ Адәмне үзе сурәте кебек итеп яралтты»* (Мөслим, «Бирр», 115).

Әлеге хәдис-шәрифтә белдерелгән хакыйкатьтә җисмани сурәт түгел, ә рухи һәм яшерен сурәт күздә тотыла. Сүз бәдән һәм нәфес түгел, рух һәм сер турында бара.

Әгәр Хәзрәти Адәмдә бу илаһи сыйфатлар бөтенесе дә чагылыш тапмаса һәм аңарда башка мәхлуклардан аерып торган өстен сыйфатлар булмаса, кеше хәлиф була алмас иде. Хәтта булган очракта да, бу вазифаны башкара алмас иде. Тик дөньяда хәлифлек вазифасын, нәфес тәрбиясе, әхлакны пакьләү һәм җанны чистарту аша узып, өлгергән камил кеше генә лаеклы рәвештә башкара ала.

Әгәр кеше, һидәят, намус, иман, Аллаһны тану һәм тәвәддүд (мәхәббәт белән дуслык саклау) кебек «Һади» сыйфаты чагылышын үстереп, тормышында алгы планга чыгарса, фәрештәләрдән дә өстенрәк дәрәҗәгә күтәрелер. Киресенчә, анда иркәлек, хәйлә, гыйбадәт кылу, инкяр итү, көнчелек һәм тәкәбберлек кебек «Музилл» исем-сыйфаты билгеләре җиңсә, хайваннардан да түбәнрәк төшәр. Моны раслап, Аллаһ Тәгалә аяти кәримәдә әйтә:

وَلَقَدْ ذَرَأْنَا لِجَهَنَّمَ كَثِيرًا مِنَ الْجِنِّ وَالْإِنسِ لَهُمْ قُلُوبٌ لَا يَفْقَهُونَ بِهَا
وَلَهُمْ أَعْيُنٌ لَا يُبْصِرُونَ بِهَا وَلَهُمْ آذَانٌ لَا يَسْمَعُونَ بِهَا أُولَئِكَ
كَالْأَنْعَامِ بَلْ هُمْ أَضَلُّ أُولَئِكَ هُمُ الْغَافِلُونَ

**«Без җеннәрдән һәм кешеләрдән күбесен** (үз теләкләре белән лаеклысын алачаклардан) **җәһәннәм өчен яралттык.** (Чөнки) **аларның йөрәкләре бар, алар белән аңламаслар. Аларның күзләре бар, алар белән күрмәсләр. Аларның колаклары бар, алар белән ишетмәсләр. Алар хайваннар кебек. Хәтта алар тагын да түбәнрәк. Алар – гафил кешеләр»** («әл-Әгъраф», 179).

Шайтанның Хәзрәти Адәмгә сәҗдә кылмавы – аның шәхесенә хас тәкәбберлек һәм горурлык чагылышы, чөнки ул бервакыт фәрештәләргә белем бирер дәрәҗәдә гыйлем иясе була. Шуңа күрә ул башкалардан өстен урын алып тора.

Бу вакыйга аша гыйлем һәм дәрәҗәнең кешеләрдә мин-минлек хисен уяту куркынычы барлыгы белдерелә. Шул ук вакытта Аллаһка итагать кылу өчен гыйлем генә җитмәгәнлегенә ишарә ителә. Шайтан төтенсез якты уттан яралтылган җеннәр төркеменнән була. Үзенең чикле акылы белән чагыштырып,

ул үзе яралтылган төтенсез якты утны Хәзрәти Адәм яралтылган балчыктан өстен, дип уйлый, чөнки шайтан аңардан курку сизә. Үз фикеренчә, тагын да кыйммәтлерәк чималдан барлыкка китерелгән һәм шәрәфлерәк мәхлукның чимал сыйфаты ягыннан түбәнрәк булган Адәмгә сәҗдә кылуын үзе өчен кимсенү саный. Бу хәл хакыйкатькә ирешү өчен акылның җитмәвенә ишарәли.

Моннан аңлашылганча, Җәнабел-Хакның әмере каршында бәхәс, бәяләү, чагыштыру булырга тиеш түгел. Изге Китап һәм сөннәткә каршы килгән чагыштырулар – ялган, бозык, аларга игътибар бирергә ярамый. Шайтан әнә шул хатаны кыла. Инде шайтанның «утның туфрактан өстенлеге» турында фикерен карыйк. Чөнки туфракның уттан өстен бик күп өстен ягы бар. Ләкин иң мөһиме – боларны чагыштыру түгел, Хак Тәгаләнең әмеренә итагать итү. Шайтанның төп гөнаһы – Хак Тәгаләнең хөкеменнән тыш хөкем чыгарырга маташуы. Чыннан да, Иблис Җәнабел-Хакка каршы кыюлык белән каршы чыга һәм ахмаклык белән:

قَالَ أَنَا خَيْرٌ مِنْهُ خَلَقْتَنِي مِنْ نَارٍ وَخَلَقْتَهُ مِنْ طِينٍ

**«”…Мин аңардан яхшыракмын, чөнки Син мине уттан яралттың, аны исә балчыктан бар иттең”, – диде»** («әл-Әгъраф», 12).[35]

Шайтан Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмнең башлангыч чималындагы балчыкны күрә белә, ә бөеклеген күрә алмый. Ул бу дөньядагы балчыкны карый, ә теге дөньяга хас рухи асылына карата сукыр кала. Шайтан белә алмаган тараф кешенең «Аллаһның хәлифе» дәрәҗәсенә билгеләнүеннән гыйбарәт, чөнки ул Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмне нәфес күзе белән бәяли. Шул рәвешле аң-зиһене Хәзрәти Адәм бар ителгән матдәдән ары китә алмый. Шайтан бәяләү өчен үлчәүне Хак Тәгаләдән түгел, үз нәфесеннән ала. Шуңа күрә аптырап кала, акыл белән түгел, хисләр белән гамәл кыла. Бу мизгелгә хәтле теләк-ниятләреннән кала, хис-тойгылар белән бәйле һичбер тәкъдим алмаган, ә мондый сынау узмаган Иблис илаһи хикмәтне аңлый алмый. Нәфес чоңгылларына батып, үз-үзендә буталып, Аллаһка каршы баш күтәрде.

Иблис үз өстенлеген югалтудан курыкканга күрә, Хәзрәти Адәмгә сәҗдә кылудан баш тарта. Ләкин бу гамәле әлеге куркуыннан да начаррак хәлгә төшерә, Аллаһ аңа насыйп иткән югары дәрәҗәле урыннан кызганыч бер рәвештә куыла. Кайчандыр фәрештәләр арасында гаять абруйга ия Иблис, алар яныннан бәхетсезлек упкынына төртеп төшерелеп, оятка калдырыла. Иблис баш күтәргәннән соң, Аллаһ Тәгалә:

قَالَ فَاخْرُجْ مِنْهَا فَإِنَّكَ رَجِيمٌ. وَإِنَّ عَلَيْكَ اللَّعْنَةَ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ

35. Шулай ук карагыз: «әл-Хиҗер», 33; «Сад», 76.

**«”Алай булса, аннан чык! Син хәзер куылган** (бер шайтан)**. Һичшиксез, ул ләгънәт сиңа җәза көненә кадәр булачак!” – дип әйтте»** («әл-Хиҗер», 34–35).

«Әгъраф» сүрәсенең 13 нче аятендә Аллаһ Тәгалә Иблискә:

قَالَ فَاهْبِطْ مِنْهَا فَمَا يَكُونُ لَكَ أَنْ تَتَكَبَّرَ فِيهَا فَاخْرُجْ إِنَّكَ مِنَ الصَّاغِرِينَ

**«”Алайса, төш моннан! Сиңа монда үзеңне әллә кемгә кую ярамас. Чык! Һичшиксез, син – хур ителгәннәрдән”, – диде».**[36]

Шулай итеп шайтан галәйһил-ләгънә, Хәзрәти Адәмгә үзенең өстенлеге турында дәгъва белдереп, фәрештәләр арасындагы абруен, югары дәрәҗәсен дә югалта. Ул, гомере өчен борчылып, Аллаһка ялварулы тавыш белән:

قَالَ رَبِّ فَأَنْظِرْنِي إِلَى يَوْمِ يُبْعَثُونَ

**«”И, Раббым! Алар терелтеләчәк көнгә кадәр миңа кичектерү бир”, – диде»** («әл-Хиҗер», 36).[37]

Илаһи хикмәт нәтиҗәсендә аңа шундый рөхсәт бирелә:

قَالَ فَإِنَّكَ مِنَ الْمُنْظَرِينَ. إِلَى يَومِ الْوَقْتِ الْمَعْلُومِ

**«Аллаһ: “Һичшиксез, син – кичектерү бирелгәннәрдән. Билгеле вакытның көненә кадәр!” – дип боерды»** («әл-Хиҗер», 37–38).[38]

Югарыда искә алынганча, Адәм галәйһиссәләм шәхесендә кыяматкәчә дөньяга килеп китәчәк бөтен кешелеккә нигез салынганлыктан, кешегә бар ителгәндә үк бирелгән хөрмәттә һәркемнең өлеше бар. Хәзрәти Адәмнең шәхесендә бөтен бәндәләрнең шайтан тарафыннан дошманлыкка дучар ителүе дә хакыйкать булып тора, чөнки колны дөньялыкта сынау өчен, бөтен нәфес омтылышларының барлыкка килүе, нәфеснең баш калкытуы кирәк. Моның өчен шайтан кебек бер котыртучы таләп ителә. Бәндәнең җәннәттән чыгарылып бу дөньяга җибәрелүенә сәбәп булган вакыйга – тыелган агачка кагылу белән бәйле хәл кешедә нәфес теләкләре барлыкка китерүдә шайтанның кыяматкәчә гамәл кылачагын күрсәтә. Чыннан да Иблис, бәндәләрнең нәфес теләк-омтылышларын уяту өчен котыртып, рухи өлгерешкә киртә кора. Шуңа күрә адәм баласы һәрвакыт уяу, сак булырга мәҗбүр.

Әнә шул хикмәтне күздә тотып, Җәнабел-Хак шайтанга кыямәт көненә кадәр вакыт биргән. Моңа каршы бер күренеш буларак, Ул бәндәләргә гафу итү, ярлыкау ишеген аларга үлем мизгеле җиткәнчегә кадәр ачык тота. Ләкин

36. Шулай ук «Сад» сүрәсенең 77–78 нче аятьләрен дә карагыз.
37. Шулай ук «әл-Әгъраф» сүрәсенең 14 нче аятен дә карагыз.
38. Шулай ук «әл-Әгъраф» сүрәсенең 15 нче аятен дә карагыз.

колны гөнаһлары сәбәпле ахирәттә бик авыр сынау көтә. «Исра» сүрәсендә шайтанның Аллаһтан рөхсәт соравы һәм Аллаһ Тәгаләнең аңа рөхсәт бирүе игътибар җәлеп итә торган рәвештә, түбәндәгечә бәян кылына:

قَالَ أَرَأَيْتَكَ هَـٰذَا الَّذِي كَرَّمْتَ عَلَيَّ لَئِنْ أَخَّرْتَنِ إِلَى يَوْمِ الْقِيَامَةِ لَأَحْتَنِكَنَّ ذُرِّيَّتَهُ إِلَّا قَلِيلًا. قَالَ اذْهَبْ فَمَنْ تَبِعَكَ مِنْهُمْ فَإِنَّ جَهَنَّمَ جَزَآؤُكُمْ جَزَاءً مَوْفُورًا. وَاسْتَفْزِزْ مَنِ اسْتَطَعْتَ مِنْهُمْ بِصَوْتِكَ وَأَجْلِبْ عَلَيْهِم بِخَيْلِكَ وَرَجِلِكَ وَشَارِكْهُمْ فِي الْأَمْوَالِ وَالْأَوْلَادِ وَعِدْهُمْ وَمَا يَعِدُهُمُ الشَّيْطَانُ إِلَّا غُرُورًا

**«**(Иблис әйтте)**: “Күрдеңме? Менә бу – Син миннән өстен иткән кемсә. Әгәр мине Кыямәт көненә кадәр кичектерсәң, бик азларыннан башка, мин аның нәселен, һичшиксез, һәлак итәчәкмен”. Аллаһ Тәгалә әйтте: “Бар! Әгәр араларыннан кем дә булса сиңа ияpсә, һичшиксез, җәһәннәм – камил дәрәҗәдәге әҗерегез булыр. Алардан көчең җиткәнне тавышың белән тайпылдыр, атлы һәм җәяүле гаскәреңне аларга каршы тупла, маллары һәм балалары мәсьәләләрендә аларга тиң бул. Шулай син аларга вәгъдә бир”. Һичшиксез, шайтан аларга алдаудан башканы вәгъдә итми»** («әл-Исра», 62–64).

Әлеге аяти кәримәләрдә шайтанның кешегә күп-күп бәлаләр китергәнлеге һәм йогынты ясаганлыгы мөһим үзенчәлекләре белән ачыклана. Алардан аңлашылганча:

– Шайтан бары үзенең көче җитә торган һәм үзенә буйсындыра алган затларга гына вәсвәсә сала ала.

– Кешене табигате белән теләк-омтылышларга бирелүчән булуы бәрабәренә һәм туры юлдан җиңел тайпылуына китерә торган һәртөрле буш сүзләр, нәфескә хуш килгән көй-җырлар ярдәмендә алдар. Аятьтә телгә алынган «саут» сүзе «кешене Аллаһка каршы килергә өндәгән теләсә нинди аваз, тавыш» дип тәфсир ителә.

– Шайтан берүзе башкарып чыга алмаган эшләрдә, вакытка һәм урынга бәйле рәвештә, кешеләр яки җеннәр арасындагы үз тарафдарларын файдалана.

– Кешеләрне күбрәк дөнья малы һәм балаларына мөнәсәбәттә вәсвәсә салу юлы белән адаштыра.

Аллаһ Тәгаләнең рөхсәтен алгач, шайтан үз нәфесендә ышаныч тоя һәм, бик зур әдәпсезлек күрсәтеп, үз кирелегенең сәбәбен Җәнабел-Хактан күрергә маташа:

قَالَ فَبِمَا أَغْوَيْتَنِي لَأَقْعُدَنَّ لَهُمْ صِرَاطَكَ الْمُسْتَقِيمَ. ثُمَّ لَآتِيَنَّهُمْ مِنْ بَيْنِ أَيْدِيهِمْ وَمِنْ خَلْفِهِمْ وَعَنْ أَيْمَانِهِمْ وَعَنْ شَمَآئِلِهِمْ وَلَا تَجِدُ أَكْثَرَهُمْ شَاكِرِينَ

**«Ул әйтте: "Мине аздырганың өчен, мин Синең туры юлыңда, һичшиксез, аларга каршы утырачакмын. Аннары мин аларга – алларыннан һәм артларыннан, уңнарыннан һәм сулларыннан киләчәкмен, һәм Син аларның күпчелеген шөкер итүчеләр буларак тапмаячаксың"»** («әл-Әгъраф», 16–17).

قَالَ رَبِّ بِمَا أَغْوَيْتَنِي لَأُزَيِّنَنَّ لَهُمْ فِي الْأَرْضِ وَلَأُغْوِيَنَّهُمْ أَجْمَعِينَ

**«**(Иблис) **әйтте: "И Раббым, мине аздырганың өчен, мин дә җирдә аларга** (гөнаһларын) **бизәп** (әшәкелекләрен матурлап) **күрсәтәчәкмен һәм аларның барысын да юлдан яздырачакмын!"»** («әл-Хиҗер», 39).

Күренекле суфи Яхья ибне Мугаз (258 (һиҗри)/872 (милади) елда вафат) шайтанның кешене котырту өчен тырышлыгын болай сурәтли:

«Шайтан – буш, ә без – мәшгуль зат, эшләребез бар. Ул безне күрә, без исә аны күрә алмыйбыз. Без онытабыз, ә ул исә үз вазифасын онытмый. Шулай ук олуг дошманыбыз булган нәфес тә шайтан файдасына көч куя».

Коръәни-Кәримдә мондый аятьләр бар:

وَلَا تَتَّبِعُوا خُطُوَاتِ الشَّيْطَانِ

**«…Шайтан юлларына иярмәгез!..»** («әл-Бәкара», 208).

إِنَّ الشَّيْطَانَ لَكُمْ عَدُوٌّ فَاتَّخِذُوهُ عَدُوّاً إِنَّمَا يَدْعُو حِزْبَهُ لِيَكُونُوا مِنْ أَصْحَابِ السَّعِيرِ

**«Һичшиксез, шайтан – сезгә дошман, сез дә аны дошман итегез. Ул тарафдарларын ут әһелләреннән булырга чакыра»** («Фатыйр», 6).

Шулай итеп, шайтанның кешеләр өчен зур һәм ачык дошман икәнлеге белдерелә һәм аның явызлыгыннан Аллаһ Тәгаләгә сыгыну кирәклеге берничә тапкыр киңәш ителә. Әлеге мәсьәлә белән башка кайбер аяти кәримәләрдә моңа басым ясала:

وَقُلْ رَبِّ أَعُوذُ بِكَ مِنْ هَمَزَاتِ الشَّيَاطِينِ. وَأَعُوذُ بِكَ رَبِّ أَنْ يَحْضُرُونِ

**«**(Әй, Хәбибем!) **Әйт: "И, Раббым! Шайтаннарның вәсвәсәләреннән Сиңа сыенамын! Аларның янымда булуларыннан** (мине адаштыруларыннан) **Сиңа сыенамын!"»** («әл-Мүэминүн», 97–98).

وَإِمَّا يَنْزَغَنَّكَ مِنَ الشَّيْطَانِ نَزْغٌ فَاسْتَعِذْ بِاللَّهِ إِنَّهُ سَمِيعٌ عَلِيمٌ.
إِنَّ الَّذِينَ اتَّقَوْا إِذَا مَسَّهُمْ طَائِفٌ مِنَ الشَّيْطَانِ تَذَكَّرُوا فَإِذَا هُمْ مُبْصِرُونَ

**«Әгәр сиңа шайтаннан бер вәсвәсә килсә, шундук Аллаһка сыен. Һичшиксез, Ул – Ишетүче, Белүче. Тәкъва кешеләр, үзләренә шайтаннан бер вәсвәсә кагыла калса,** (Аллаһның кушканнарын һәм тыюларын) **искә төшерәләр һәм алар аңлы рәвештә хакыйкатьне күрәләр»** («әл-Әгъраф», 200–201).

Сыену, дигәндә, куркыткан берәр нәрсәдән саклану өчен, башка бер зат ярдәменә таяну, аның яклавын тою, аның кочагына керү күздә тотыла, шайтанның андый вәсвәсәсеннән саклана алу өчен, Җәнабел-Хак, «Нәс» сүрәсендә «Раббы», «Мәлик», «Илаһ» сыйфатларын искә алып, бары тик үзенә генә сыенырга боера, чөнки кешеләрне алдау өчен һәр ысулны сынаган һәм бөтен көчен сарыф иткән шайтанның явызлыгыннан бердәнбер Аллаһ Тәгалә генә саклый ала.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә шайтаннан саклану өчен «бисмилла» әйтергә киңәш бирә:

*«Берәү өенә кергәндә һәм ашаганда «бисмилла» әйтсә, шайтан үз гаскәренә: "Монда төн куна һәм ризык ашый алмассыз", – дип әйтер. Әгәр ул зат өйгә кергәндә "бисмилла" әйтмәсә, шайтан аларга: "Төн кунар урын таптыгыз", – дип әйтер. Ул кеше ашаганда "бисмилла" әйтмәсә, шайтан үз гаскәренә: "Менә яшәр урын да, ашар ризык та таптыгыз", – дип әйтер»* (Мөслим, «Әшрибә», 103).

Шайтан явызлыгыннан саклануның башка бер ысулы – ихлас гамәл кылу. Аяти кәримәләрдә:

إِلَّا عِبَادَكَ مِنْهُمُ الْمُخْلَصِينَ

«(Колларыңның барчасын аздырачакмын) **Синең ихлас колларыңнан башка!»** («әл-Хиҗер», 40).

إِنَّ عِبَادِي لَيْسَ لَكَ عَلَيْهِمْ سُلْطَانٌ إِلَّا مَنِ اتَّبَعَكَ مِنَ الْغَاوِينَ

**«Һичшиксез, сиңа ияргән адашучылардан тыш, минем** (ихлас) **колларыма синең көчең** (һәм сулышың) **җитмәс»**, – диелә («әл-Хиҗер», 42).

Ихласлык – гыйбадәттә һәм башка гамәлләрдә рияга юл куймау, гыйбадәттә һәм Аллаһка итагатьтә кеше күрсен өчен генә эшләүдән һәм йөрәкнең сафлыгын пычрата торган нәрсәләрдән тыелу дигәнне белдерә. Бары Аллаһ ризалыгын гына уйлап гамәл кылу, бары Аллаһ өчен генә гыйбадәт дигән сүз.

Шуңа күрә ихласлык кешегә шайтан матурлап күрсәтергә тырышкан әшәкелекләргә һәм шайтанның кешеләрне аздырырга маташуына комачаулый торган көбә вазифасын башкара. Ихласлыкка ирешү өчен, бәндәнең йөрәге белән билгеле бер дәрәҗәгә күтәрелүе һәм Аллаһны танып белүдә үзенә өлеш алуда тырышлык куюы зарур.

Аллаһ Тәгаләне йөрәк һәм тел белән зикер кылу да шайтанның явызлыгыннан саклануның иң нәтиҗәле ысулларыннан берсе санала. Зикердән туктау исә шайтанның яныбыздан һич китмәвенә бер сәбәп булыр. Бөтен гөнаһлар һәрвакыт Аллаһ Тәгаләне оныткан чакта эшләнә, чөнки кеше «бисмилла» әйтеп, гөнаһ кыла алмас, «Аллаһ» дип, ниндидер хаксызлык, начарлык эшли, кемнедер рәнҗетеп, йөрәгенә энә батыра алмас. Җәнабел-Хак ошбу хикмәтне болай ачыклый:

وَمَنْ يَعْشُ عَنْ ذِكْرِ الرَّحْمنِ نُقَيِّضْ لَهُ شَيْطَانًا فَهُوَ لَهُ قَرِينٌ

**«Кем дә кем Рахманның зикереннән сукыр калырга тырышса** (гафләткә китеп, зикердән баш тартса)**, Без аның яныннан китмәячәк бер шайтан куячакбыз»** («әз-Зүхруф», 36).

Шайтаннан саклануның мөһим алымы – Аллаһка һәм Аның Рәсүленә, ягъни исламга ихлас күңелдән буйсыну һәм ила-и кәлиматуллаһ (Аллаһның исемен югары күтәрү) өчен бар көчебез белән тырышлык күрсәтүдән гыйбарәт. Бөек Раббыбыз:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنْ تَنْصُرُوا اللَّهَ يَنْصُرْكُمْ وَيُثَبِّتْ أَقْدَامَكُمْ

**«И, иман китерүчеләр! Сез Аллаһка** (ягъни Аның диненә) **ярдәм итсәгез, Ул да сезгә ярдәм итәчәк һәм аякларыгызны** (туры, дөрес юлда) **нык итәчәк»**, – дип әйтә («Мөхәммәд», 7).

Аллаһ Тәгаләнең әмерен кире кагып, шайтанга иярүчеләрнең барачак җире җәһәннәм икәнлеге анык белдерелә:

لَأَمْلأَنَّ جَهَنَّمَ مِنْكَ وَمِمَّنْ تَبِعَكَ مِنْهُمْ أَجْمَعِينَ

**«Җәһәннәмне синең һәм алардан сиңа ияргәннәр белән тутырачакмын»** («Сад», 85).

لَمَنْ تَبِعَكَ مِنْهُمْ لَأَمْلأَنَّ جَهَنَّمَ مِنْكُمْ أَجْمَعِينَ

**«...Кодрәтем белән ант итәм: алардан кем дә кем сиңа ияреп булса, сезнең барчагыз белән җәһәннәмне тутырачакмын!»** («әл-Әгъраф», 18).

Бу очракта безгә йөкләнгән вазифа – Аллаһ Тәгалә белдергәнчә, шайтанның дошман икәнлеген тану һәм аның, без җәһәннәмгә ташлансын өчен, һәртөрле хәйлә-мәкергә баруын онытмау.

Риваятькә күрә, фәрештәләр Хәзрәти Адәмгә сәҗдәдән башларын күтәргәндә, «Газазил» исеме белән билгеле һәм бик күп гыйбадәттә булуы белән танылган җенне, ягъни шайтанны, сәҗдәдән баш тарткан һәм ямьсез кыяфәткә кергән хәлдә күреп алалар. Шуннан соң Аллаһ Тәгаләнең әмеренә итагать кылу нигъмәтенә шөкер кылу өчен, алар барысы бергә кабат сәҗдәгә каплана.

Сәҗдәдән ваз кичкәч, «Шайтан» кушаматын алган Газазил явызлык вәкиленә әверелә. Ул фәрештә түгел, ә җәннәттәге фәрештәләр арасында уттан яралтылган бер җен була. Шуңа күрә үзенең яралтылуын ул өстенрәк дип саный һәм Хәзрәти Адәмнең Аллаһ үзе өреп керткән рухка ия булуы һәм Аның хәлифе вазифасын башкаруы кебек өстенлекләрен төшенә алмый. Аллаһ Тәгаләнең әмеренә карата гафиллек күрсәтеп, нәфес коллыгына төшә. Аллаһ Тәгалә аңардагы гаҗизлек, наданлык һәм гафиллеккә түбәндәгечә ишарәли:

مَا أَشْهَدْتُهُمْ خَلْقَ السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ وَلَا خَلْقَ أَنْفُسِهِمْ
وَمَا كُنْتُ مُتَّخِذَ الْمُضِلِّينَ عَضُدًا

**«Мин аларны** (Иблис һәм аның нәселен) **күкләрнең һәм җирнең яралтылышына да, шәхсән үзләренең яралтылышына да шаһитлык итмәдем. Мин юлдан язганнарны беркайчан да ярдәмче итмим»** («әл-Кәһф», 51).

Башка аяти кәримәдә Җәнабел-Хак колларын, яратылу максатыннан ерагаеп, шайтан һәм аның яраннарын дус күрү белән бәйле игътибарсызлыктан кисәтеп куя:

كَانَ مِنَ الْجِنِّ فَفَسَقَ عَنْ أَمْرِ رَبِّهِ أَفَتَتَّخِذُونَهُ وَذُرِّيَّتَهُ أَوْلِيَاءَ
مِنْ دُونِي وَهُمْ لَكُمْ عَدُوٌّ بِئْسَ لِلظَّالِمِينَ بَدَلًا

**«...Иблис җеннәрдән иде, Раббысының әмереннән чыкты. Хәзер сез Мине ташлап, аны һәм аның нәселен дус итмәкчесезме? Алар бит – сезнең дошманнарыгыз. Залимнәр өчен бу нинди яман алмашу!»** («әл-Кәһф», 50).

Аллаһ Тәгаләнең фәрештәләргә: «Адәмгә сәҗдә кылыгыз!» дигән боерыгы һич тә «Адәмгә гыйбадәт кылыгыз, ягъни кол булыгыз», дигән мәгънә белдерми, ә Хәзрәти Адәмнең сәләтләре һәм күркәм сыйфатлары белән алардан өстенрәк икәнлеген күрсәтү өчен кирәк була, чөнки Җәнабел-Хак аны башкалардан аерып торган сыйфатларга ия зат итеп бар кыла һәм аңа үз рухыннан җан өрә.

Башка бер сәбәп – сәҗдә белән бәйле әмергә «Аллаһның кушканын үтәгез!» дигән мәгънә салынуда. Чөнки Хәзрәти Адәмгә карата башкарылган бу сәҗдә хакыйкатьтә шәхсән Аллаһка итагать, Аңа гыйбадәт кылуны белдерә. Чынлыкта Хәзрәти Адәм әлеге сәҗдәдә Кәгъбә кебек кыйбла ролен үти, чөнки Кәгъбәгә юнәлеп сәҗдәгә китү Кәгъбәгә гыйбадәт кылуны аңлатмый. Кәгъбә – Җәнабел-Хак тарафыннан күрсәтелгән, Аның колларының гыйбадәтен тәртипкә салган һәм Аның рәхмәте чагылыш тапкан бер урын ул.

**Хәзрәти Хәүва анабызның яралтылуы**

Хәзрәти Хәүваның Адәм галәйһиссәләмнән яралтылуы белән бәйле аяти кәримәләрдә Бөек Раббыбыз болай дип хәбәр итә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ
وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً

**«И, кешеләр! Сезне бер җаннан** (Адәмнән) **яралткан, аның бер кисәгеннән ишен** (Хәүваны) **яралткан һәм аларның икесеннән бик күп ирләр белән хатыннарны халикъ кылып тараткан Раббыгыздан куркыгыз!..»** («ән-Ниса», 1).

هُوَ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ نَفْسٍ وَاحِدَةٍ وَجَعَلَ مِنْهَا زَوْجَهَا لِيَسْكُنَ إِلَيْهَا

**«Ул сезне бер җаннан** (Адәмнән) **яралтты һәм аның бер кисәгеннән, аңарда тынычлык тапсын, дип, ишен** (Хәүваны) **яралтты...»** («әл-Әгъраф», 189).

Җәнабел-Хакның мәңгелектә бердәнберлеге турында югарыда төрлечә искә алдык. Аны танысыннар, белсеннәр өчен дигән максат белән мәхлуклар бар итelә һәм күбәйтелә, күплекләр дөньясы буларак билгеле бу галәм барлыкка китерелә. Бу исә Аллаһ Тәгаләнең үзен тануларын сөюенә бәйле, шуңа күрә һәм мәхлукның яралтылу сәбәбе мәхәббәттән гыйбарәт, аерым алганда, Җәнабел-Хакның Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә карата мәхәббәтеннән. Әлеге хикмәт кодси хәдистә телгә алына.[39]

Бу үзенчәлек Адәм галәйһиссәләм өчен дә туры килә. Ләкин бу мәхәббәт һәм теләк-ниятнең камил максаты – ихлас гыйбадәт кылып, төп асылга, ягъни Раббыга кайту омтылышы. Моның өчен исә билгеле бер хәзерлек этабы рәвешендәге башлангыч таләп ителә.

Бердәнберлекне бары тик үзенә генә хас итеп билгеләгән Аллаһ Тәгалә шул нигездә һәр мәхлукны каршы җенестәге вәкиле белән бергә парлы итеп яралта һәм аларда бер-берсенә карата әсирлек, якынлык булдырган, үз

39. Хәдис-шәрифне китапның 107–108 нче битләреннән укый аласыз.

араларында сөйкемлелек, тартылу барлыкка китергән. Чыннан да бу дөнья күзәнәкләр, төшләр, үсемлекләр, хайваннар, кеше, матдәләр, атомнар һәм атом эчендәге электрон һәм протон кебек кисәкчекләргә кадәр бөтен нәрсә, төзелешенә, эчтәлегенә карап, парлы яралтылу канунына буйсына. Моны раслап аяти кәримәдә:

وَمِنْ كُلِّ شَيْءٍ خَلَقْنَا زَوْجَيْنِ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ

**«Һәрнәрсәдән ике иш яралттык. Бәлки, сез фикерләп карарсыз»**, – диелә («әз-Зарият», 49).

Бу үзенчәлек бер үк вакытта мәхлукның Раббысына кайту теләген чынга ашыру өчен дә кирәк. Күплек галәме булган бу дөньядан бердәнберлек, мәңгелек галәменә кайту табигый дә, мәҗбүри дә шарт, омтылыш булып тора. Үзара иш парлар арасында бер-берсенә омтылыш табигатьтән килә һәм әнә шул мәңгелеккә күпер һәм нигез тәшкил итә. Шул ук вакытта Аллаһ Тәгалә парлылык хәлен нәселләрне дәвам итү өчен дә бер сәбәп, нигез итеп яралткан.

Башка яктан караганда, Аллаһ яралткан бәндә Яралтучысыннан никадәр читләшсә, туган туфрагыннан шулкадәр ерактарак дигән сүз. Туган җирдән аерылу ялгызлыкка, чарасызлыкка, нәтиҗәдә исә кайгы-хәсрәткә китерә, кешедә ниндидер юанычка, ярдәм эзләүгә ихтыяҗ тудыра. Шул сәбәпле: «Ялгызлык Аллаһка гына хас!» – диелә. Аннан кала һәрнәрсәнең юатучыга һәм үзенә карата игътибарга ихтыяҗы бар. Барлык бу табигый үзенчәлекләр, җәннәттә һәрнәрсә тулып торуга карамастан, Адәм галәйһиссәләмдә «миңа тиң бер иш булдырылса иде», дигән теләк тууын бер зарурлыкка әйләндерә. Шул рәвешле Ләйлә-Мәҗнүн риваятьләрендә сөйләнгән мәхәббәтнең, ахыр чиктә бу Ләйләләрне узып, Хак Тәгаләгә күчешен тәэмин итәчәк күпер булдыру шарты чынга ашырыла. Шуңа күрә дә Ләйләләр белән башланган мәхәббәт хисләре Аллаһка мөнәсәбәттә тынычлык, иминлеккә әйләнгәндә генә, билгеле бер мәгънәгә ия булыр. Югыйсә Ләйләләр потка әверелеп, дөньялыктагы авыр сынау уңышсыз төгәлләнеп, бу дөнья алдану мәйданы булып чыгачак. Ләйлә – бер символ гына, ул ниндидер хатын-кызны, дәрәҗәне яисә акчаны белдерә. Нәфеснең башка төрле омтылышы да булырга мөмкин. Аларга ияргән кеше нәфесен илаһка әйләндерә, дип әйтергә була.

Җәнабел-Хак, бик күп хикмәтләрне күздә тотып, Адәм галәйһиссәләмгә аңа тынычлык һәм рәхәтлек китерәчәк иш яралтырга ниятли. Шуннан соң Адәмнең сул кабырга сөяген гүя бер үсенте кебек файдаланып, аның үз тореннән булган Хәзрәти Хәуваны яралта.

Ибне Габбас һәм Ибне Мәсгуд радыйаллаһу ганһүмәдән килгән риваятькә күрә, *Иблис җәннәттән чыгарылып, анда Адәм галәйһиссәләм урнаштырыла. Адәм атабыз җәннәттә күңелен күтәрерлек һичкеме, ише булмыйча, ялгыз гына гизеп йөри. Андагы нигъмәтләрнең күплегенә карамастан, ул Раббысын-*

*нан үзенә иш сорый. Беркөнне йокысыннан уянуга, баш очында сул кабыргадан яралтылган бер хатын күрә һәм аңардан:*

*«Син кем?» – дип сорый. Ул исә:*

*«Мин хатын-кыз», – дип җавап бирә.*

*Адәм аның ни өчен яралтылуын белергә теләгәч:*

*«Аллаһ мине сиңа минем белән юаныч һәм рәхәтлек тапсын өчен яралтты», – ди.*

*«Җанлы, терелек иясе» дигән мәгънә белдергән Хәүва исеме аңа «Хәйй», ягъни «тере» Адәмнән яралтылганлыгы аркасында бирелә* (Табәри, «Тарих», I, 103–104).

Бохари тапшырган риваятькә күрә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Хатын-кызларга игелекле мөнәсәбәттә булыгыз, чөнки хатын-кыз кабырга сөягеннән яралтылган. Кабырга сөягенең иң кәкре өлеше – өске ягы. Аны турайтырга маташсаң, сынар, үз хәленә кайтарсаң, һәрвакыт кәкре булып калыр. Шуңа күрә хатын-кызларга йомшак мөгамәлә кылыгыз»,* – дип әйткән (Бохари, «Әнбия», 1).

Җәнабел-Хак хис-тойгы ягыннан хатын-кызны ир-атка караганда баерак итеп яралткан. Аяти кәримәдә бала яралуның башлангыч этабы тасвирланганда, ир-аттан килгән өлешнең «сулб – бил сөяге» тирәсеннән, хатын-кыздан килгән өлешнең исә «тәраиб – йөрәк янында урнашкан, хис үзәге булган күкрәк сөякләре» арасыннан чыкканлыгы белдерелә.[40] Бу исә хатын-кызның хис-тойгы дөньясы бай икәнлегенә ишарәли. Әлеге хис-тойгы байлыгы – хатын-кызга Аллаһ йөкләгән төп вазифаның шарты. Бу вазифа исә нәселне саклау һәм тәрбияләүдән гыйбарәт. Шуңа күрә хатын-кызларга йомшак мөгамәләдә булу таләп ителә. Ата кеше баланы ана кебек карый алмый, астын алыштыра алмый, бала өчен йокыдан баш тартмый. Бала бәлагә тарыса, ана үзен корбан итәргә әзер, ир-ат моңа сәләтле түгел. Ана кеше һәрвакыт балаларын кайгыртып, аларны сөеп яши. Ана баланы тугыз ай карынында, ике ел кочагында, гомер буе исә йөрәгендә йөртә. Бала ашамаса-эчмәсә ана кешенең йокысы кача. Сабый еласа, ана да яшь түгәр. Шуңа күрә ана хакын һичничек түләп бетереп булмый.

Хәүва анабызны яралтканнан соң, Җәнабел-Хак:

وَيَا آدَمُ اسْكُنْ أَنْتَ وَزَوْجُكَ الْجَنَّةَ فَكُلَا مِنْ حَيْثُ شِئْتُمَا
وَلَا تَقْرَبَا هٰذِهِ الشَّجَرَةَ فَتَكُونَا مِنَ الظَّالِمِينَ

40. Карагыз: «әт-Тарик», 6–7 нче аятьләр.

**«И, Адәм! Син хатының белән бергә җәннәттә урнаш. Үзегез теләгән урыннан ашагыз, әмма шушы агачка якын килмәгез, юкса икегез дә золым иткән кешеләрдән булырсыз»**, – дип боера («әл-Әгъраф», 19).

Шулай итеп, шәрәфле мәхлук булган кешенең сынаулардан торган тормыш маҗарасы башлана.

### Җәннәт тормышы

Хәзрәти Адәм белән Хәүва галәйһимәс-сәләмне яралтканнан соң, Аллаһ Тәгалә аларның һәртөрле нигъмәтләр белән тулган җәннәттә яшәвенә, тыелган агачтан кала, җәннәтнең бар нигъмәтләреннән теләгәнчә куллануларына рөхсәт бирә. Шулай ук Иблиснең аларга ачык дошман булуы турында да хәбәр итә. Әлеге илаһи кисәтү аяти кәримәдә түбәндәгечә белдерелә:

فَقُلْنَا يَا آدَمُ إِنَّ هَذَا عَدُوٌّ لَكَ وَلِزَوْجِكَ فَلَا يُخْرِجَنَّكُمَا مِنَ الْجَنَّةِ فَتَشْقَى.

**«И, Адәм! Бу –** (шайтан) **синең дә, хатыныңның да** (ап-ачык) **дошманы. Ул сезне җәннәттән чыгара күрмәсен, югыйсә, интегерсең!»** («Та-һә», 117).

Адәм белән Хәүва җәннәттә рәхәт һәм бивафа гомер кичерә. Аяти кәримәдә бу болай телгә алына:

إِنَّ لَكَ أَلَّا تَجُوعَ فِيهَا وَلَا تَعْرَى. وَأَنَّكَ لَا تَظْمَأُ فِيهَا وَلَا تَضْحَى

**«Син монда ачыкмассың һәм киемсез дә калмассың. Һичшиксез, син биредә сусызлыктан да тилмермәссең, эсселектән дә интекмәссең!»** («Та-һә», 118–119).

Хәзрәти Адәм белән Хәүва галәйһимәс-сәләм шул рәвешле җәннәттә яшәп ятканда, шайтан аларның зәгыйфь хисләрен һәм мәңгелек тормышка кызыгуларын файдаланып, тыелган агачның җимешен татып каравына сәбәп була.

### Җәннәттән җиргә төшерелү

Аллаһ Тәгаләнең үз колларын сынавы Аның Хәзрәти Адәмне яралткан чакта ук билгеләп куйган илаһи максаты булып тора. Белгәнебезчә, иң әүвәл фәрештәләр сынау уза, Хәзрәти Адәмгә сәҗдә кылырга кушу әнә шул имтихан була. Бөтен фәрештәләр дә бу сынауны уңышлы тапшыра, чөнки аларга киреләнү, каршы килү кебек гамәлләргә китергән нәфес омтылышы хас түгел. Шайтан исә баш күтәрә, чөнки ул нәфескә ия җеннәр төркеменнән була.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү фәрештәләрне һәм шайтанны Хәзрәти Адәм белән сынагач, Адәм галәйһиссәләм һәм аның хатыны Хәүвага Иблис белән имти-

хан уздыра. Шуңа күрә Иблискә андый форсат бирә. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Хәзрәти Адәм белән Хәзрәти Хәүвага җәннәттәге бер агачка кагылуны тыя.

Кешенең Аллаһ әмеренә буйсынуына комачауларга тырышкан нәфес шайтан вәсвәсәсе аркасында үз хуҗасы белән тәүге көрәшен башлый. Кайбер риваятьләрдә Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмнең тыелган агачка кагылуында Хәзрәти Хәүваның йогынтысы булганлыгы әйтелә.

Хатын-кызлар – Җәнабел-Хак тарафыннан ир-атларга караганда хисләрәк, матуррак яралтылган нәфис затлар. Шунлыктан чит тәэсиргә җиңелрәк бирешәләр. Хатын-кызларның әнә шул үзенчәлеген файдаланып, шайтан Адәм галәйһиссәләмне һәм аның нәселен station аздырырга тырыша һәм күп очракта уңышка ирешә. Чыннан да хәзерге заманда иҗтимагый тормышның сәясәткә, икътисадка һәм сәүдәгә бәйле барлык тарафларында хатын-кызның реклама һәм пропаганда чарасы буларак кулланылуы – моның иң күзгә ташланып торган бер мисалы. Хатын-кыз бер ягы белән зиннәт һәм иминлек чыганагы булса, икенче яктан ул – бик зур сынау чарасы да. Фәкать бәндәнең дөнья һәм ахирәт бәхете дә янә хатын-кызга бәйле. Моны Сәүбән радыйаллаһу ганһе болай бәян кыла:

وَالَّذِينَ يَكْنِزُونَ الذَّهَبَ وَالْفِضَّةَ وَلَا يُنْفِقُونَهَا فِي سَبِيلِ اللّٰهِ فَبَشِّرْهُم بِعَذَابٍ أَلِيمٍ

**«…Алтын һәм көмеш җыйган һәм аларны Аллаһ юлында сарыф итмәгән кешеләрне тилмерткеч бер газап белән “сөендер”!»** аяте («әт-Тәүбә», 34) иңгәндә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән бергә сәфәрдә чагыбыз иде. Кайбер сәхабәләр:

«Алтын һәм көмеш турында иңдереләсе иңде (Инде башка аларны һич җыймабыз). Кайсы нәрсәнең хәерлерәк икәнен белеп, шуны бераз үзебезгә алсак иде?» – диделәр.

Шуннан соң Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Үзең ия булган нәрсәләрнең иң фазыйләтлесе – зикер кыла торган тел, шөкер итә торган йөрәк һәм иренең иманына ярдәм итүче булган тәкъва хатын»*, – дип җавап бирде (Тирмизи, «Тәфсир», 9/9).

Бүтән хәдис-шәрифләрдә исә болай диелә:

*«Мөэмин, Аллаһка тәкъвалыктан соң, иң күбе иманлы хатыннан игелек күрер. Мондый хатынга нидер кушса, ул буйсыныр, аңа карап торса, шатлык тояр, нинди дер гамәлне эшләү-эшләмәүгә ант биргән булса, хатын моны үзе эшләп, аны антын бозудан коткарыр, хатынын калдырып берәр ерак җиргә китсә, ул хатын һәм үз намусы, һәм иренең мөлкәте мәсьәләсендә хәерхаһлы һәм дөрес гамәл кылыр»* (Ибне Мәҗә, «Никах», 5/1857).

*«Дөнья файдалы нигъмәтләр белән тулы. Бу нигъмәтләрнең иң хәерлесе исә – иманлы хатын»* (Мөслим, «Рада», 64; Нәсаи, «Никах», 15; Ибне Мәҗә, «Никах», 5).

Шуңа күрә Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе «Бәкара» сүрәсендәге 201 нче аятьнең гомуми мәгънәсе менә болай да тәфсир ителә алганын белдергән:

«Аятьтә телгә алынган «رَبَّنَا آتِنَا فِي الدُّنْيَا حَسَنَةً» “Раббыбыз, безгә дөньялыкта яхшыны бир” дигән сүзләр – “Раббыбыз, безгә дөньялыкта иманлы хатын бир”; «وَفِي الْآخِرَةِ حَسَنَةً» “Ахирәттә дә яхшыны насыйп ит” өлеше – “Ахирәттә дә хурул-гыйнне (җәннәттәге хур кызлары) насыйп ит”; «وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ» “Безне җәһәннәм газабыннан сакла” өлеше исә “Безне хатын-кызларның мәкереннән һәм ялкытуыннан сакла!” дигән мәгънә белдерә» (Гали әл-Кари, «Миркат», VI, 265).

Шайтан галәйһил-ләгънә, үзенә тигән вазифасы кушканча, Хәзрәти Адәм белән Хәуваны алдау, күндерү өчен төрле хәйләгә бара. Алар аяти кәримәләрдә бәян кылына:

فَوَسْوَسَ إِلَيْهِ الشَّيْطَانُ قَالَ يَا آدَمُ هَلْ أَدُلُّكَ عَلَى شَجَرَةِ الْخُلْدِ وَمُلْكٍ لَا يَبْلَى

**«Соңыннан шайтан аңа: “И, Адәм! Мәңгелек агачын һәм бетми торган хакимлекне сиңа күрсәтимме?” – дип вәсвәсә кылды»** («Та-һә», 120).

فَوَسْوَسَ لَهُمَا الشَّيْطَانُ لِيُبْدِيَ لَهُمَا مَا وُورِيَ عَنْهُمَا مِنْ سَوْآتِهِمَا وَقَالَ مَا نَهَاكُمَا رَبُّكُمَا عَنْ هٰذِهِ الشَّجَرَةِ إِلَّا أَنْ تَكُونَا مَلَكَيْنِ أَوْ تَكُونَا مِنَ الْخَالِدِينَ. وَقَاسَمَهُمَا إِنِّي لَكُمَا لَمِنَ النَّاصِحِينَ. فَدَلّٰيهُمَا بِغُرُورٍ فَلَمَّا ذَاقَا الشَّجَرَةَ بَدَتْ لَهُمَا سَوْآتُهُمَا وَطَفِقَا يَخْصِفَانِ عَلَيْهِمَا مِنْ وَرَقِ الْجَنَّةِ وَنَادَاهُمَا رَبُّهُمَا أَلَمْ أَنْهَكُمَا عَنْ تِلْكُمَا الشَّجَرَةِ وَأَقُلْ لَكُمَا إِنَّ الشَّيْطَانَ لَكُمَا عَدُوٌّ مُبِينٌ

**«Шайтан: “Ике фәрештә булырсыз яки икегез дә мәңге** (җәннәттә) **калучылардан булырсыз, дип, Раббыгыз сезгә бу агачны тыйды”, – диде һәм аларның капланган гаурәтләрен үзләренә күрсәтер өчен икесенә дә вәсвәсә бирде. Ул икесенә дә ант итте: “Һичшиксез, мин икегез өчен дә нәсыйхәт бирүчеләрдәнмен”. Ул бер хәйлә белән икесен дә алдады. Һәм алар икесе дә ул агачтан татып карагач, гаурәтләре үзләренә ачылды, һәм алар өсләренә җәннәт яфраклары ябыштыра башладылар.[41] Раббы-**

41. Киенү, каплану – мәхлуклар арасында кешегә генә хас халәт. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү насыйп кылган кешелек дәрәҗәсен, горурлыкны, оят һәм җитдилекне саклый алу өчен, бәндә киенергә, капланырга мәҗбүр. Югыйсә әлеге сыйфатларына зыян килер һәм үзеннән түбәнрәк мәхлуклар дәрәҗәсенә төшәр. Җәмгыятьтә оят югалу ахырзаман галәмәтләренең берсе санала. Хәдис-шәрифтә: «Оят имандадыр!» – дип белдерелә (Бохари, «Иман», 3). Җәннәттә башка кешеләр булмаса да, Хәзрәти Адәм белән Хәува бер-берсеннән һәм бүтән мәхлуклардан ояла. Алар, борчылып, шундагы яфраклар белән капланырга тырыша. Бу исә шуны раслый: матди тараф буларак каплану, киенү һәм аның рухи чагылышы булган әдәп һәм оят – адәм баласының иң өстен сыйфатларыннан.

**лары аларга эндәште: “Сезнең икегезгә дә бу агачны тыймаган идемме, сезгә “һичшиксез, шайтан – сезнең икегезгә дә ап-ачык бер дошман”, димәгән идемме?”»** («әл-Әгъраф», 20–22).

Хәзрәти Адәм һәм Хәуваның тыелган агачка кагылуы аларның нәфес киртәсе белән моңарчы очрашмаганлыклары аркасында була, чөнки яуланган нәтиҗәнең хакы аңа ирешү өчен узылган мәшәкатьләргә нисбәтле. Нәфес, аңа ияргән вакытта, һәлакәткә китерсә, тәрбияләнеп, буйсындырылса, уңыш чыганагына, бәхет чишмәсенә әйләнә. Шунлыктан: «Нәфесегез – сезнең атланып йөри торган атыгыз ул! Аңа яхшы һәм йомшак мөгамәләдә булыгыз», – дип әйтәләр.

Кыскасы, бердәнбер һәм булмышы мотлак Аллаһ Тәгалә үзенең һәрнәрсәгә кодрәтле ихтыяры белән бәндәгә чикләнгән ихтыяр гына бирә һәм ахыр нәтиҗәне бу теләк-ихтыярның ничек кулланылуына карап, хөрмәт яки хәсрәт тәкъдир кыла. Сәбәпләрнең хакыйкый шартларын да шуннан чыгып тәртипкә сала. Шуңа күрә без Аның бүләге булган чикле ихтыярыбызны үзебезгә башта ук кушылганча кулланырга һәм, Аның каһәреннән куркып, Аның хәеренә сыенуда бурычлыбыз.

Шайтанның үзләреннән үч алу өчен кылган хәйләсенә алданган Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм белән аның хатыны Хәзрәти Хәува, бик күңелсезләнеп, шундук Иблистән баш тарталар. Фәрештәләргә билгеләнгән юлны өстен күреп, Раббыларыннан аңлап алган сүзләр белән тәүбәгә бирелеп,[42] Аңа:

رَبَّنَا ظَلَمْنَا أَنْفُسَنَا وَإِنْ لَمْ تَغْفِرْ لَنَا وَتَرْحَمْنَا لَنَكُونَنَّ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«…И, Раббыбыз! Без үз-үзләребезгә золым иттек. Әгәр дә Син безне гафу итмәсәң һәм безгә мәрхәмәт итмәсәң, без зарар күргәннәрдән булырбыз»**, – дип ялваралар («әл-Әгъраф», 23).

Җәнабел-Хак аларның тәүбәсен кабул итә, фәкать бик күп илаһи хикмәтне чынга ашырып, аларның җиргә төшерелүен тели һәм:

قَالَ اهْبِطُوا بَعْضُكُمْ لِبَعْضٍ عَدُوٌّ وَلَكُمْ فِي الْأَرْضِ مُسْتَقَرٌّ
وَمَتَاعٌ إِلَى حِينٍ. قَالَ فِيهَا تَحْيَوْنَ وَفِيهَا تَمُوتُونَ وَمِنْهَا تُخْرَجُونَ

**«Әйтте: “Бер-берләрегезгә дошман буларак**[43] (җиргә) **чыгыгыз. Сезгә яшәү урыны һәм вакытлыча файдалану урыны – җирдә”. Әйтте: “Анда**

42. Карагыз: «Әл-Бәкара», 37.
43. Мондагы «дошман» сүзе шайтан һәм җеннәр белән кешеләр арасында, шулай ук кешеләрнең үз араларында төрле сәбәпләр аркасында килеп чыгачак һәм кыяматкәчә дәвам итәчәк дошманлыкны күздә тота.

**яшәячәксез, анда үләчәксез һәм аннан чыгарылачаксыз”»** («әл-Әгъраф», 24–25).

Аллаһ, тәүбәләрен кабул итеп, Хәзрәти Адәм белән Хәүвага һәм аларның нәселләренә котылу юлын түбәндәгечә аңлатып бирә:

يَا بَنِي آدَمَ قَدْ أَنْزَلْنَا عَلَيْكُمْ لِبَاسًا يُوَارِي سَوْاتِكُمْ وَرِيشًا وَلِبَاسُ التَّقْوَى ذٰلِكَ خَيْرٌ

**«И, Адәм балалары! Без сезгә гаурәтләрегезне каплар өчен бер кием һәм зиннәт иңдердек. Тәкъвалык киеме моннан яхшырак…»** («әл-Әгъраф», 26).

Бу аять, кешенең гөнаһларын һәм кимчелекләрен каплар өчен, тышкы киеме генә җитмәвенә, чын киемнең исә, йөрәкне тискәре хис-тойгылар һәм фикерләрдән саклап, колның Аллаһ каршындагы җаваплылыгын аңлавын тәэмин иткән «тәкъвалык киеме» икәнлегенә ишарәли. Башка бер аяти кәримәдә Җәнабел-Хак өстенлеккә бары йөрәкләрдәге тәкъвалык белән ирешеп булачагын белдерә:

إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِنْدَ اللهِ أَتْقَيكُمْ

**«…Шөбһәсез, Аллаһ хозурында иң кадерлегез – бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз…»** («әл-Хуҗурат», 13).

Аллаһ Тәгалә «Әгъраф» сүрәсенең 27 нче аятендә үз колларын кисәтеп куя:

يَا بَنِي آدَمَ لَا يَفْتِنَنَّكُمُ الشَّيْطَانُ كَمَا أَخْرَجَ أَبَوَيْكُمْ مِنَ الْجَنَّةِ
يَنْزِعُ عَنْهُمَا لِبَاسَهُمَا لِيُرِيَهُمَا سَوْاتِهِمَا إِنَّهُ يَريكُمْ هُوَ وَقَبِيلُهُ مِنْ حَيْثُ
لَا تَرَوْنَهُمْ إِنَّا جَعَلْنَا الشَّيَاطِينَ أَوْلِيَاءَ لِلَّذِينَ لَا يُؤْمِنُونَ

**«И, Адәм балалары! Икесенә дә гаурәтләрен күрсәтер өчен, киемнәрен салдырып, ата-анагызны җәннәттән чыгарган кебек, шайтан сезне дә адаштырмасын. Һичшиксез, ул, гаскәрләре белән бергә, сез аларны күрә алмаган җирдән сезне күрә. Һичшиксез, Без шайтаннарны иман итмәгән кешеләргә дуслар иттек».**

Җәнабел-Хак бөтен кешеләрнең ата-бабасы булган Адәм галәйһиссәләмне, мәхлукларның иң хөрмәтлесе итеп, җәннәттә яралта. Ләкин тыелган агачка кагылулары нәтиҗәсендә, ул асыл «бар ителгән» ватаны – җәннәттән чыгарыла да имтихан галәме булган бу дөньяга җибәрелә. Бу хәлнең кайбер хикмәтләрен шушы рәвешле аерып карарга була:

1. Адәм галәйһиссәләм һәм Хәүва анабыздан дәвам итәчәк кешелек нәселенең җирдә яшәве максат итеп куела.

2. Үзләре яралтылган җәннәттәге нигъмәтләрнең кыйммәтен, кадерен белеп, кабат шул нигъмәтләргә кайту өмете белән, сынау урыны булган бу дөньяда изге гамәлләргә омтылуы хуплана.

3. Адәм галәйһиссәләм нәсел-нәсәбе арасында, җәннәткә лаек булмыйча, җәһәннәмгә атылырга тиешле затларның изге кешеләрдән аерылып торуы тормышка ашырыла.

4. Аллаһ хөкемнәрен һәм Аның кушканнарын үтәп, кешенең бу җирне матурлап, анда хәлиф булып торуы ниятләнә.

5. Адәмнең җиргә төшерелүенең асылына кеше акылы аңлый алмаячак тәкъдир сере салынган.

**Кешедәге рухи халәтнең зәгыйфь урыннары**

Җәнабел-Хак кеше табигатенә әхлаксызлык һәм тәкъвалык орлыкларын салып куйган һәм аңа ике юнәлештә дә үсәргә (яки түбән төшәргә) мөмкинлек калдырган. Бу тарафтан караганда, кешенең күңеленә уңай һәм тискәре рухи халәт хас. Кешене нәфеснең куркыныч котыртуларына бирешүдән саклау, аны хәерле гамәлләргә һәм тәкъвалыкка юнәлтү өчен, Коръәни-Кәримдә күбрәк кеше психологиясенең зәгыйфь якларына игътибар бирелә.

**1. Кеше бик залим һәм надан.**

Аяти кәримәдә болай диелә:

إِنَّا عَرَضْنَا الْأَمَانَةَ عَلَى السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ وَالْجِبَالِ فَأَبَيْنَ أَنْ يَحْمِلْنَهَا
وَأَشْفَقْنَ مِنْهَا وَحَمَلَهَا الْإِنْسَانُ إِنَّهُ كَانَ ظَلُومًا جَهُولًا

**«Без ул әманәтне күкләргә, җиргә һәм тауларга тәкъдим иттек, ләкин алар аны өсләренә алудан баш тарттылар һәм аңардан (җаваплылыгыннан) курыктылар. Кеше исә аны өстенә алды. Һичшиксез, ул залим һәм надан булды»** («әл-Әхзәб», 72).

Аяти кәримәдә телгә алган «әманәт», гомумән алганда, кешенең Раббысы каршында җаваплылыкны, ягъни дини әмерләрне үтәүдә җаваплы булуын белдерә. Кеше бу әманәтне «акыл» һәм моны куллану сәләте булган «ихтыяр» күнекмәләре ярдәмендә җиренә җиткерәчәк. Тик кешегә бирелгән бу әманәт – аны бүтән мәхлуклардан аерып торган сыйфат ул. Кешенең дөнья тормышында сыналуы да әлеге әманәтнең аңа бирелүе аркасында.

Аяти кәримәдә әманәтнең җирләргә, күкләргә һәм тауларга тәкъдим ителүе, аларның исә бу тәкъдимне кире кагуы, җансыз предметлар буларак билгеле нәрсәләрнең дә әманәт җаваплылыгының авырлыгын аера алырлык аң-зиһенгә ия булуын күрсәтә.

لَوْ أَنْزَلْنَا هَذَا الْقُرْآنَ عَلَى جَبَلٍ لَرَأَيْتَهُ خَاشِعًا مُتَصَدِّعًا مِنْ خَشْيَةِ اللَّهِ وَتِلْكَ الْأَمْثَالُ نَضْرِبُهَا لِلنَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَتَفَكَّرُونَ

**«Әгәр дә Без бу Коръәнне бер тауга иңдергән булсак, син аны Аллаһтан куркудан буйсынган хәлдә яргаланганын күрер идең. Бу мисалларны Без кешеләргә фикерләсеннәр дип китерәбез»**, аяти кәримәсеннән дә («әл-Хәшер», 21) аңлашылганча, җансыз нәрсә булган таулар да илаһи әмерләргә каршы хис һәм гамәл белән җавап бирергә сәләтле икән.

Җәнабел-Хак аяти кәримәдә кешенең, бик залим һәм надан булганы өчен, җаваплылыктан курыкмавы һәм «әманәт» йөген үзенә алуын белдерә.

Золымның антонимы – «гаделлек». «Гаделлек» сүзе бер үк вакытта изге гамәл дигән мәгънәдә дә кулланыла, шуңа күрә, золым чоңгылына төшмәс өчен, күп-күп изге гамәлләр кылырга тырышырга кирәк. Чыннан да Җәнабел-Хак «Гаср» сүрәсендә, кайгы-хәсрәттән котылу өчен, бәндәнең изге гамәл кылучы булырга тиешлеге әйтелә.

Наданлыкның антонимы исә – «гыйлем». Гыйлем дә яшерен һәм ачык гыйлем рәвешендә икегә аерып карала. Имам Газали куддисә сирруһ хакыйкый гыйлемнең шушы ике төрле гыйлемне бергә колачлавына бәйле рәвештә:

«Чын галимнәр, ягъни пәйгамбәр варислары – ачык һәм яшерен гыйлемнәрне берләштерүче галимнәр ул!» – дип аңлата.

Җәнабел-Хак башка аяти кәримәдә:

أَمَّنْ هُوَ قَانِتٌ آنَاءَ اللَّيْلِ سَاجِدًا وَقَائِمًا يَحْذَرُ الْآخِرَةَ وَيَرْجُو رَحْمَةَ رَبِّهِ قُلْ هَلْ يَسْتَوِي الَّذِينَ يَعْلَمُونَ وَالَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ إِنَّمَا يَتَذَكَّرُ أُولُوا الْأَلْبَابِ

**«Үзен Ахирәттән саклаган һәм Раббысының рәхмәтен өмет итеп төн сәгатьләрендә сәҗдә кылып һәм кыямда торып, итагать иткән кешеме соң** (ул инкяр итүче кебек)**! Әйт** (Рәсүлем!)**: “Белгән кешеләр белән белмәгән кешеләр тиң була аламы?” Аек акылларга ия кешеләр генә үгетләнә»**, – дип белдерә («әз-Зүмәр», 9).

Әз-Зәмахшәри әлеге аяти кәримәнең тәфсирендә болай ди:

«Аллаһ Тәгалә “белүчеләр, белгән кешеләр” сүзе белән итагать итүче һәм гыйбадәт кылучы затларны, “белмәүчеләр, белмәгән кешеләр” сүзе белән исә андый сыйфатка ия булмаган адәм балаларын атый. Шул рәвешле Хак Тәгалә итагать итүче һәм гыйбадәт кылучыларны галимнәр дип саный, шул ук вакытта гамәлсез килеш кенә чын галим дәрәҗәсенә ирешеп булмаячагына да басым ясый. Шунлыктан бу аятьтә аз гыйлемле, итагатьсез һәм гыйбадәт кылмаучы, үзләрендәге барлы-юклы белемнәргә алданып, дөньялыкта фетнә чыгарган

затларга бик зур гаеп белдерелә. Менә кемнәр ул – Аллаһ каршында җаһил бәндәләр» («Кәшшаф», V, 156).

Аяти кәримәләргә ярашлы рәвештә, «изге гамәлләр» иясе булып, ачык һәм яшерен белемнәребезне Аллаһны танып белүгә әйләндерә алган кадәр дәрәҗәдә без «залим» һәм «җаһил» сыйфатларыннан арынырбыз, ягъни әлеге рухи авыруларны дәвалау өчен, белем капиталы белән бергә йөрәк капиталы, рухи капитал да кирәк.

Шулай ук югарыдагы аяти кәримәләрдә Аллаһ Җәллә Җәләлүһү илаһи серләр һәм илаһи бөеклектән бихәбәр яшәве нәтиҗәсендә кеше дучар булачак бәхетсезлек турында да хәбәр итә.

Мәснәвиләрне шәрехләүче Таһир әл-Мәүләви кеше үзенә йөкләгән җаваплылыкның авырлыгын болай сурәтли:

*«Буш кул белән барылмас барасы җиргә;*
*Раббым, буш килмәдем мин, гөнаһ алып килдем!..*

*Таулар күтәрә алмаган ул авыр йөкне*
*Ике кат авыррак итеп аркамда алып килдем!..»*

Суфилар фикеренчә, кешенең төп сыйфаты белемсезлектән гыйбарәт. Аяти кәримәдә «бик надан» дип әйтелү – моңа бер дәлил. Абсолют гыйлем бары Аллаһка гына хас. Моны Җәнабел-Хак:

وَمَا أُوتِيتُمْ مِنَ الْعِلْمِ إِلَّا قَلِيلًا

**«...Сезгә исә гыйлемнән аз бер өлеш кенә бирелде»**, – дип раслый («әл-Исра», 85). Моңа өстәп, Җәнабел-Хак гыйлеменең чиксезлеген һәм бөеклеген белдергән түбәндәге аяти кәримә игътибарга лаек:

وَلَوْ أَنَّ مَا فِي الْأَرْضِ مِنْ شَجَرَةٍ أَقْلَامٌ وَالْبَحْرُ يَمُدُّهُ مِنْ بَعْدِهِ
سَبْعَةُ أَبْحُرٍ مَا نَفِدَتْ كَلِمَاتُ اللّٰهِ إِنَّ اللّٰهَ عَزِيزٌ حَكِيمٌ

**«Әгәр дә җирдәге һәрбер агач каләмнәр булса, ул диңгез исә** (язу карасы булып) **артыннан тагын җиде диңгез аның карасын арттырса, Аллаһның сүзләре** (язылып) **бетмәс иде, чөнки, һичшиксез, Аллаһ – Бөек, Хикмәт иясе»** («Локман», 27).

Түбәндәге хәдис-шәрифтә дә әнә шул хакыйкать турында бик ачык сөйләнә:

*«Хозыр галәйһиссәләм Муса галәйһиссәләмгә гаҗәеп, искиткеч һәм асыл хикмәте билгесез вакыйгалар күрсәткән сәяхәт вакытында бер чыпчык алар барган корабның борт читенә куна. Аннары томшыгы белән диңгездән су*

*ала. Хозыр галәйһиссәләм, бу күренешкә Муса галәйһиссәләмнең игътибарын юнәлтеп, мондый чагыштыру китерә:*

*“Аллаһның гыйлеме янында синең, минем һәм бөтен мәхлукларның гыйлеме шушы кошның томшыгы белән диңгездән алган суы кадәр”»* (Бохари, «Тәфсир», 18/4).

Галимнәр әлеге риваятькә һәм башка шуңа охшашларына нигезләнеп, түбәндәге нәтиҗәгә килә. Кешеләрнең гыйлеме Аллаһның әүлиялары гыйлеме янында дәрьядан бер тамчыга тиң; әүлиялар гыйлеме пәйгамбәрләрнеке янында дәрьядан бер тамчы кебек; пәйгамбәрләрнең гыйлеме Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гыйлеме янында дәрьядан бер тамчы кебек һәм Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең гыйлеме исә Аллаһныкы янында дәрьядан бер тамчы нисбәтендә.

Ләкин үзенә бирелгән шул аз күләмдәге гыйлем белән гамәл кылып, тәкъвалыкка ирешергә насыйп булса, Аллаһның рәхмәте һәм юмартлыгы белән бәндә гариф дәрәҗәсенә менәр. Шул рәвешле Аллаһны тиешенчә танып белү мөмкинлегеннән үзенә тигән өлешне ала башлар һәм аңа илаһи серләр ачылыр. Моны раслап, аяти кәримәдә:

وَاتَّقُوا اللّٰهَ وَيُعَلِّمُكُمُ اللّٰهُ

**«…Аллаһтан куркыгыз. Аллаһ сезгә** (ихтыяҗ кичергән нәрсәләрне) **өйрәтә...»** – диелә («әл-Бәкара», 282).

Мөфәссир Куртуби әлеге аяти кәримәнең тәфсирендә:

«Бу аятьтә Аллаһтан курыкканнарга Аллаһның үзе гыйлем өйрәтәчәге вәгъдә ителә. Ягъни тәкъвалык иясе булган колның йөрәгенә Җәнабел-Хак хикмәтләрне төшендерәчәк һәм хак белән ялганны аера алачак бер нур кертеп җибәрер», – дип аңлатма бирә (Куртуби, III, 406).

Хәдис-шәрифтә әлеге мәгънә тагын да ныгытыла:

*«Өйрәнгәннәре белән гамәл кылучыга Аллаһ Тәгалә ул белмәгәннәрне өйрәтер»* (Әбу Нугайм, «Хильятүл-Әвлия», X, 15).

**2. Кеше ашыгучан була.**

Аллаһ Тәгалә кеше психологиясенең әлеге үзенчәлеген анык белдерә:

خُلِقَ الْإِنْسَانُ مِنْ عَجَلٍ

**«Кеше ашыгучан** (табигатьле) **яралтылган…»** («әл-Әнбия», 37).

وَيَدْعُ الْإِنْسَانُ بِالشَّرِّ دُعَاءَهُ بِالْخَيْرِ وَ كَانَ الْاِنْسَانُ عَجُولًا

**«Яхшылык теләгәне кебек, кеше начарлык белән дога кыла. Кеше бит – бик ашыгучан!»** («әл-Исра», 11).

Үзенә хәерлене сораган кебек, кеше начарлыкны да теләп ала һәм гамәлләре белән начарлыкны чакырып китерә. Моның сәбәбе кешенең бик ашыгучанлыгы белән бәйле. Сабыр-түземлек кыен булганга күрә, бәндә соңрак буласы нәрсәнең хәзер үк, вакытыннан алдарак үзенә насыйп ителүен тели. Мондый мөнәсәбәт вакыт-вакыт һич көтелмәгән нәтиҗәгә китерергә мөмкин. «Мәҗәлләә»дә: «Кем бер нәрсәнең вакытыннан алда, ашыгып килүен теләсә, мәхрүмлек белән җәзаланыр», – диелә, ягъни нәрсәнең дә булса вакытыннан алдарак, ашыгыч рәвештә чынга ашуын теләгән зат шул нәрсәдән мәхрүм ителү җәзасын татыр.

Кешенең ашыгучанлык сыйфаты аның теләгенә бик җиңел ирешү омтылышында чагылыш таба, чөнки адәм баласы ахирәт бәхетен дөньялыкта тоярга тели. Шуңа күрә кешеләрнең күбесе, ахирәт турында онытып, дөньялыкка күңел бирә. Ул бөек ахирәт бүләгенә әһәмият бирмәгән кебек, бик газаплы җәза турында да уйлап карамый. Кабаланучанлыгы аркасында яхшы белән начарны аермаганга күрә, киләчәге турында фикерләми. Аяти кәримәдә кешенең шул рәвешле алдануы турында болай диелә:

كَلَّا بَلْ تُحِبُّونَ الْعَاجِلَةَ وَتَذَرُونَ الْآخِرَةَ

**«Юк шул! Сез ашыга торганын (дөнья тормышын) сөясез. Ахирәтне исә кире кагасыз»** («әл-Кыямә», 20–21).

Чыннан да, бәндә, ачуы кабарган, берәр бәлагә тарыган, төрле авырлыкларга очраган вакытта, башкаларга бик җиңел бәддога яудырырга мөмкин. Хәлбуки, мондый читен һәм бәла-казалы хәлләрдән сабыр-түземлек белән чыгарга кирәк. Әмма кабаланучан табигате аркасында бәндә андый вазгыятьләрдә, өметсез һәм пессимистик күңел халәтендә килеш кайчак хис-тойгыларга бирелеп: «Аллаһым, җанымны ал да мине бу бәладән коткар!» –кебек сүзләр белән үзенә дә бәддога укыр. Бу гамәл тамырдан хаталы.

Әнәс радыйаллаһу ганһедән бәян кылына:

«Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бик хәлсезләнгән бер авыруның хәлен белергә бара һәм аннан:

*«Аллаһка берәр нәрсә өчен дога кыла идеңме яки Аңардан берәр нәрсә сорый идеңме?»* – дип сорый. Авыру кеше:

«Әйе. Аллаһым, миңа ахирәттә бирәчәк җәзаңны бу дөньяда алдан биреп куй, дип дога кыла идем», – дип җавап бирә.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Сөбханаллаһ! Синең моңа көчең җитмәс. Менә болай дога кылсаң, ярамас идеме: “Аллаһым! Безгә дөньялыкта да игелек бир, ахирәттә дә игелек бир һәм безне җәһәннәм газабыннан сакла!”* – диде.

Шуннан соң авыру бәндә шул доганы укый, шифа таба» (Мөслим, «Зикер», 23/2688; Тирмизи, «Дәгъват», 71/3487).

Бүтән бер хәдистә Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең болай дип әйтүе тапшырыла:

*«Башыма бер бәла килде, дип, һичберегез үлем теләмәсен. Һичшиксез шундый нәрсә теләргә мәҗбүр хәлдә калса, андый кеше: “Аллаһым, минем өчен яшәү хәерле булган вакыт аралыгында мине яшәт, шәхесемә үлем хәерле булган вакытта исә, җанымны ал”, – дип әйтсен»* (Бохари, «Мәрда», 19; «Дәгъват», 30; Мөслим, «Зикер», 10, 13).

Шуңа күрә мөэминнәр бәддога кылырга тиеш түгел. Хәерлегә ирешү өчен, сабырлык һәм аек акыл белән дога укырга, игелекле эшләр башкарып, яхшылыкка өндәргә кирәк. Аяти кәримәдә киңәш ителгәнчә:

رَبَّنَآ اٰتِنَا فِى الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِى الْاٰخِرَةِ حَسَنَةً وَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

**«…Раббыбыз! Безгә дөньяда да яхшы нәрсәләр бир, Ахирәттә дә яхшы нәрсәләр бир һәм безне утның газабыннан сакла»**, – дип ялвару тиеш («әл-Бәкара», 201).

**3. Кеше үз мәнфәгатен кайгыртучан.**

Кешенең бу сыйфатын белдергән бер аяти кәримәдә:

وَإِذَا أَذَقْنَا النَّاسَ رَحْمَةً فَرِحُوا بِهَا وَإِن تُصِبْهُمْ سَيِّئَةٌ بِمَا قَدَّمَتْ أَيْدِيهِمْ إِذَا هُمْ يَقْنَطُونَ

**«Без кешеләргә бер рәхмәт татыттырган чагыбызда, аңа сөенәләр. Әмма куллары кылган нәрсәләр сәбәпле аларга зарар килсә, алар өметләрен өзәләр»**, – дип әйтелә («әр-Рум», 36).

Асылда, Аллаһның рәхмәте һәм юмартлыгына сөенү тыелмаган, киресенчә, әмер ителгән.[44] Ләкин бу сөенечтә максат, нигъмәт бирүчене танып, мактау-олуглау һәм шөкер итү кирәклеген аңлап шатланудан гыйбарәт. Монда исә нигъмәт бирүчене искә алмыйча, бары нигъмәт белән горурланып, борын чөйгән һәм нәфесенә ияргән затларның хәле аңлатыла. Коръән сүзләре белән әйткәндә:

…لَا تَفْرَحْ إِنَّ اللهَ لَا يُحِبُّ الْفَرِحِينَ

44. Карагыз: «Йуныс» сүрәсе, 58.

**«...Сак бул, тәкәбберләнеп сөенмә! Һичшиксез, Аллаһ** (тәкәбберләнеп) **сөенүчеләрне сөйми!»** («әл-Касас», 76). Андый затлар гыйбадәт кылсалар да, аны дөнья мәнфәгатен кайгыртып эшләрләр. Бары нигъмәткә генә ышанганнарына күрә, башларына берәр бәла-каза килсә, шундук өметсезлеккә төшәләр. Аллаһның рәхмәтеннән тулысынча өметләрен өзәрләр, чөнки алар үз-үзләрен мәңгелек булган Аллаһка түгел, фани нәрсәләргә багышлыйлар. Кешенең мәнфәгате турында кайгыртучанлыгы аяти кәримәдә бик матур тасвирлана:

وَمِنَ النَّاسِ مَنْ يَعْبُدُ اللَّهَ عَلَى حَرْفٍ فَإِنْ أَصَابَهُ خَيْرٌ اطْمَأَنَّ بِهِ وَإِنْ أَصَابَتْهُ فِتْنَةٌ انقَلَبَ عَلَى وَجْهِهِ خَسِرَ الدُّنْيَا وَالْآخِرَةَ ذَلِكَ هُوَ الْخُسْرَانُ الْمُبِينُ

**«Кешеләр арасында шундые бар, бер чиктә Аллаһка** (шөбһә һәм икеләнү тоеп) **гыйбадәт кыла. Әгәр аңа хәерле нәрсә килсә, шуның белән тынычланыр. Әмма аңа бер сынау-каза кагылса, ягына кабат кайта** (диннән йөз чөерә)**. Ул дөньяны да, ахирәтне дә югалта. Менә бу – ап-ачык бер зарар»** («әл-Хаҗ», 11).

Андый бәндә дә, нәфес теләкләреннән котыла алмаган өчен, үз белдегенчә Аллаһка гыйбадәт кыла, билгеле бер максатларны күздә тотып, гафил рәвештә диндар булып йөри. Мондый кешеләрнең теленнән зикер өзелми, ләкин ул йөрәкне саклауда катнашмый. Андый бәндә үзенә берәр яхшылык килсә, сөенә, ә берәр нинди бәла-каза килсә, хакыйкатьтән йөз чөерә.

**4. Кеше Аллаһка карата рәхмәтсез.**

Аяти кәримәдә:

إِنَّ الْإِنْسَانَ لِرَبِّهِ لَكَنُودٌ. وَإِنَّهُ عَلَى ذلِكَ لَشَهِيدٌ

**«Һичшиксез, кеше – Раббысына шөкер кылмаучы. Һәм, һичшиксез, ул моңа үзе шаһит»**, – дип әйтелә («әл-Гадият», 6–7).

«Исра» сүрәсеннән түбәндәге аятьләр исә гафил бәндәнең әлеге үзенчәлеген гаять үтемле аңлатып, мондый типтагы рухи халәтләрнең, тирә-юнь шартларыннан чыгып, ничек үзгәргәне турында бәян кылына:

وَإِذَا مَسَّكُمُ الضُّرُّ فِي الْبَحْرِ ضَلَّ مَنْ تَدْعُونَ إِلَّا إِيَّاهُ فَلَمَّا نَجّيكُمْ إِلَى الْبَرِّ أَعْرَضْتُمْ وَكَانَ الْإِنْسَانُ كَفُورًا. أَفَأَمِنْتُمْ أَنْ يَخْسِفَ بِكُمْ جَانِبَ الْبَرِّ أَوْ يُرْسِلَ عَلَيْكُمْ حَاصِبًا ثُمَّ لَا تَجِدُوا لَكُمْ وَكِيلًا. امْ أَمِنْتُمْ أَنْ يُعِيدَكُمْ فِيهِ تَارَةً أُخْرَى فَيُرْسِلَ عَلَيْكُمْ قَاصِفًا مِنَ الرِّيحِ فَيُغْرِقَكُم بِمَا كَفَرْتُمْ ثُمَّ لَا تَجِدُوا لَكُمْ عَلَيْنَا بِهِ تَبِيعًا

**«Диңгездә сезгә бер зарар кагылгач, Аннан башка табынган нәрсәләрегез юкка чыга. Әмма Ул сезне корыга коткаргач,** (кабат иске хәлегезгә кайтып) **йөз чөерәсез. Һичшиксез, кеше игелек кадерен белми. Әллә сез Аның сезне коры җирнең бер өлешенә батырмавыннан яки өстегезгә ташлы өермә җибәрмәвеннән иминлектәме? Ул вакыт бит үзегезгә бер Яклаучы да таба алмассыз. Яки тагын бер мәртәбә сезне аңа** (диңгезгә) **кайтаруыннан, шуннан соң өстегезгә кырып бетерә торган җил җибәрүеннән һәм, шөкер итә белмәвегез сәбәпле, сезне суга батыруыннан иминлектәме? Аннары моның өчен, Безгә каршы үзегезгә** (үч алырга) **бер шәфәгатьче дә таба алмаячаксыз»** («әл-Исра», 67–69).

Башка бер аяти кәримәдә адәм баласының игелексезлеге түбәндәгечә искә алына:

فَأَمَّا الْإِنْسَانُ إِذَا مَا ابْتَلِيهُ رَبُّهُ فَأَكْرَمَهُ وَنَعَّمَهُ فَيَقُولُ رَبِّي أَكْرَمَنِ.
وَأَمَّا إِذَا مَا ابْتَلِيهُ فَقَدَرَ عَلَيْهِ رِزْقَهُ فَيَقُولُ رَبِّي أَهَانَنِ

**«Әмма кеше Раббысы аны сынап хөрмәтләгән һәм нигъмәт биргән чакта: "Раббым миңа хөрмәт күрсәтте!" – дип әйтә. Әмма аны сынап ризыгын тарайткан чакта: "Раббым мине хур итте!" – дип әйтә»** («әл-Фәҗер», 15–16).

Бөек Раббыбыз колын, аның сабырлыгына нисбәтле рәвештә бүләкләр өчен, һәр мизгелдә сынап тора. Шундый вакытта ризыгы азайтылган, төрле бәла-казаларга тарыган бик күп бәндәләр моның Аллаһ каршында хисап тотканда бер җиңеллек, ахирәттә бик зур әҗергә әйләнәчәген, димәк, чынлыкта илаһи нигъмәт һәм Аның саклавы-яклавы икәнлеген төшенмичә: «Раббым мине кимсетте, мине читкә этәрде», – дип үпкәли. Раббының аларга җибәрелгән нигъмәтләрен аңлый алмас дәрәҗәгә җитәләр. Аларның хәтта аз булган ризыкка да шөкер итәргә тиешлекләрен, азның кыйммәтен белмәүчене муллыкның кадерен белә алмаячагын төшенү сәләтен югалталар. Раббының шул рәвешле үзләрен сынаганын акылларына китереп тә карамыйлар. Чынлыкта Җәнабел-Хак:

وَنَبْلُوكُم بِالشَّرِّ وَالْخَيْرِ فِتْنَةً

**«...Без, коткы салыр өчен, сезне яманлык белән дә, яхшылык белән дә сыныйбыз...»** – дип анык белдереп куя («әл-Әнбия», 35). Адәм баласы бу хәлләрнең хикмәтен аңламаса, тискәре хис-тойгылар ахыр чиктә аны көферлеккә сөйрәп, аны яралтучы Бөек Раббысына каршы килү дәрәҗәсенә җиткерә ала, чөнки бәндә фазыйләткә түгел, ә дөньялыктагы вакытлы, буш теләкләренә йөз тота. Аяти кәримәдә адәм баласының рәхмәтсезлеге һәм Аллаһка каршы килүе анык әйтелә:

خَلَقَ الْإِنْسَانَ مِنْ نُطْفَةٍ فَإِذَا هُوَ خَصِيمٌ مُبِينٌ

**«**(Аллаһ) **кешене бер тамчыдан яралтты. Шуннан соң да ул ачык рәвештә Раббысы белән бәхәсләшә!»** («ән-Нәхел», 4).[45]

**5. Кеше саран һәм ачкүзле.**

Кешенең җәннәттән чыгарылуында зур өлешне алып торган бу начар сыйфатлар, тәрбия нәтиҗәсендә йөгәнләнмәсәләр, дөнья һәм мәңгелек тормышы өчен иң зур куркынычларның берсенә әйләнә. Раббыбыз мөэмин затта мондый сыйфатлар булуын теләми. Җәнабел-Хак бу мәсьәләдә колларын кисәтеп куя:

كَلَّا بَلْ لَا تُكْرِمُونَ الْيَتِيمَ. وَلَا تَحَاضُّونَ عَلَى طَعَامِ الْمِسْكِينِ.
وَتَأْكُلُونَ التُّرَاثَ أَكْلاً لَمّاً. وَتُحِبُّونَ الْمَالَ حُبًّا جَمًّا

**«Юк! Сез ятимгә хөрмәт күрсәтмисез. Бер-берегезне мескенне ашатырга өндәмисез. Хәрәм белән хәләлне аермыйча, комсызланып, мирасны ашыйсыз. Малны чиксез яратасыз!»** («әл-Фәҗер», 17–20).

إِنَّ الْإِنْسَانَ خُلِقَ هَلُوعاً. إِذَا مَسَّهُ الشَّرُّ جَزُوعاً. وَإِذَا مَسَّهُ الْخَيْرُ مَنُوعًا

**«Һичшиксез, кеше сабырсыз буларак яралтылган. Аңа начарлык кагылган чакта кайгыручан. Аңа яхшылык кагылган чакта исә, саранланыр»** («әл-Мәгариҗ», 19–21).

وَإِنَّهُ لِحُبِّ الْخَيْرِ لَشَدِيدٌ

**«Һичшиксез, кеше малны бик нык ярата»** («әл-Гадият», 8).

Аяти кәримәдә дөнья малына карата «хәер» сүзенең куллану сәбәбе кеше табигатенең шуңа омтылуы белән бәйле, чөнки күпчелек бәндәләр дөньялыктагы мәнфәгатьләре аркасында мал-мөлкәтне һичшиксез «хәерле нәрсә» дип күзаллый, аятьтә мондый караш тәнкыйтьләнә. Адәм баласы мал-мөлкәтне һичшиксез «хәерле нәрсә» дип санап, байлык ратканга күрә саранлана, комсызлана. Аллаһ ризалыгы өчен ул байлык белән бүлешергә, аны хәер-сәдакага тотарга, гавам мәнфәгатенә багышларга теләми, малын җәлли. Байлыкка ирешү мәсьәләсендә бик көчле һәм комсыз булса, ул мал-мөлкәтнең бер өлешен бүлешеп, шөкер кылуга килгәндә, бәндә Аллаһ юлында сарыф итүдән кача башлый, үзенең зәгыйфьлеге турында сөйләргә керешә, рәхмәтсез кылана. «Каләм» сүрәсендә Аллаһ биргән нигъмәтләргә рәхмәтсез, шөкерсез бакча хуҗалары дучар булган бәла-каза мисалында комсызларны нинди язмыш

45. Карагыз: «Йәсин» сүрәсе, 77.

көтүе турында хәбәр ителә.[46] Мондый начар сыйфатка ия бәндәләрне Җәнабел-Хак болай дип кисәтә:

وَيْلٌ لِكُلِّ هُمَزَةٍ لُمَزَةٍ. الَّذِي جَمَعَ مَالًا وَعَدَّدَهُ. يَحْسَبُ أَنَّ مَالَهُ أَخْلَدَهُ. كَلَّا لَيُنْبَذَنَّ فِي الْحُطَمَةِ

**«Кешеләрне артта яманлаучы** (һүмәзә) **һәм йөзгә карап мыскыл итүче** (лүмәзә) **һәр кемсәгә ни үкенеч! Ул күп мал җыйган да шуны каткат саный. Ул малын мәңге кылачак дип саный. Юк! Ул Хутәмәгә ыргытылачак»** («әл-Һүмәзә», 1–4).

قُلْ لَوْ أَنْتُمْ تَمْلِكُونَ خَزَآئِنَ رَحْمَةِ رَبِّي إِذًا لَأَمْسَكْتُمْ خَشْيَةَ الْإِنْفَاقِ وَكَانَ الْإِنْسَانُ قَتُورًا

**«Әйт: “Әгәр дә сез Раббымның рәхмәт хәзинәләренә ия булсагыз, шул чакта да ярлыланудан куркып тотар идегез. Һичшиксез, кеше – бик саран”»** («әл-Исра», 100).

**6. Кеше көнче һәм хөсетле.**

Көнчелек, хөсетлек – кеше табигатендәге тискәре сыйфатларның иң куркынычларыннан. Аяти кәримәләрдә мондый юллар бар:

وَأُحْضِرَتِ الْأَنفُسُ الشُّحَّ

**«…Саранлык җаннарга бик якын тора…»** («ән-Ниса», 128).

أَمْ يَحْسُدُونَ النَّاسَ عَلَى مَا آتَاهُمُ اللَّهُ مِنْ فَضْلِهِ

**«Әллә соң алар Аллаһ Үзенең фазылыннан кешеләргә биргән нәрсәләрдән көнләшәләрме?..»** («ән-Ниса», 54).

Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм, хөсетлектән тыеп, аның зыяны турында болай дип хәбәр бирә:

**«Көнчелектән тыелыгыз, чөнки ялкын утынны ашап бетергән кебек, көнчелек игелекле гамәлләрне ашап бетерер»** (Әбү Давыт, «Әдәб», 44).

Әлеге әшәке сыйфаттан котылу өчен, Җәнабел-Хак инфак[47] һәм исарга[48] әһәмият бирергә кирәклеген белдерә:

وَمَنْ يُوقَ شُحَّ نَفْسِهِ فَأُولَئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ

**«…Кем дә кем нәфесенең комсызлыгыннан саклана, шулар – уңышка ирешүчеләр»** («әл-Хәшер», 9).

46. Карагыз: «әл-Каләм» сүрәсе, 16–33.
47. Инфак – Аллаһ юлында сарыф итү.
48. Исар – үзең дә мохтаҗ хәлдә, башкалар белән бүлешү.

**7. Кеше зәгыйфь итеп яралтылган.**

Аллаһ Тәгалә башка мәхлукларны туганнан соң бик кыска вакыт эчендә аякка басарлык һәм шундук үзләре тормыш алып барырлык дәрәҗәдә көчле итеп яралтса, кешене шактый озак вакытка бүтәннәр ярдәменә, бүтәннәрнең яклавына, саклавына мохтаҗ итеп, гаҗиз, зәгыйфь итеп бар кыла. Аяти кәримәдә бу үзенчәлек турында:

اَللّٰهُ الَّذِي خَلَقَكُمْ مِنْ ضَعْفٍ ثُمَّ جَعَلَ مِنْ بَعْدِ ضَعْفٍ قُوَّةً ثُمَّ جَعَلَ مِنْ بَعْدِ قُوَّةٍ ضَعْفًا وَشَيْبَةً

**«Аллаһ сезне бер зәгыйфьлектән яралтты, аннары зәгыйфьлек артыннан куәт бирде, шуннан соң куәт артыннан көчсезлек һәм чал** (картлык) **бирде...»** – дип әйтелә («әр-Рум», 54).

Көче ташып торган яшьлек чорына алданып, кеше Аллаһка каршы баш күтәрергә, киреләнергә тиеш түгел, чөнки бу көч-куәтле вакыттан соң, һичшиксез, зәгыйфьлек һәм хәлсезлек чоры киләчәк. Картлыктагы үкенеч хисе исә кулдан ычкындырган форсатларны кире кайтармый, җанның кайгы-борчуын, күңел газабын баса алмый. Кешенең ахырда аяныч хәлдә калуы аяти кәримәдә болай аңлатыла:

وَمَنْ نُعَمِّرْهُ نُنَكِّسْهُ فِي الْخَلْقِ أَفَلَا يَعْقِلُونَ

**«Без кемгәдер озын гомер бирсәк, аның** (көч-куәтен алып) **яралтылышта киресен әйләндерәбез. Әллә алар** (бу күренешне) **аңламыйлармы** (әлеге гыйбрәтле сәфәр турында төшенмиләрме)**?»** («Йәсин», 68).

Физиологик төзелеше белән шактый күп зәгыйфь урыннары булган адәм баласына, асылда, психологик яктан тагын да зуррак зәгыйфьлек хас. Ике тарафны да күзаллаган аяти кәримәдә:

وَخُلِقَ الْإِنْسَانُ ضَعِيفًا

**«…Кеше зәгыйфь буларак яралтылган»**, – дип әйтелә («ән-Ниса», 28).

Ихтыяр көче, хәтер һәм көчлелек ягыннан кешенең зәгыйфьлеген Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм шәхесе мисалында Җәнабел-Хак болай дип искә ала:

وَلَقَدْ عَهِدْنَا إِلَى آدَمَ مِنْ قَبْلُ فَنَسِيَ وَلَمْ نَجِدْ لَهُ عَزْمًا

**«Без моннан алда Адәмгә дә** (тыелган агачтан ашамау турында) **әмер биргән идек. Ләкин ул онытты. Без аңарда катгый карар тапмадык»** («Таһә», 115).

Шулай итеп, «инсан» (кеше) сүзенең ике аерым тамырдан ясалган булуы әйтелә. Беренчесе – «онытма» дигән мәгънәсендәге «нисьян». Аяти кәримәдә

белдерелгәнчә, Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм Аллаһка биргән антын оныта. Икенчесе исә – «үнсият», кеше үзе булган җиргә бик тиз ияләшә, тамырлары белән берегә һәм, гадәттә, шул җирлекнең төсмерләрен үзенә сеңдерә.

Аллаһ Тәгаләнең берничә аяти кәримәсендә зәгыйфьлекләре һәм гаҗизлекләре турында сөйләнгән адәм улларын горурланырга һәм тәкәбберләнергә мәҗбүр иткән һичбер сәбәп булырга мөмкин түгел. Өстәвенә, Җәнабел-Хак кешене сөйкемле һәм хуш күренә торган маңгай тире яки күз яшеннән түгел, кыйммәте булмаган, түгелгән бер су тамчысыннан яралткан. Шуңа күрә кеше Яралтучысының иксез-чиксез кодрәте каршында үзенең гаҗиз булуын һәм әһәмиятсезлеген аңларга тиеш. Чыннан да, кеше бу мәсьәләдә шулай кисәтелгән:

وَلَا تَمْشِ فِي الْأَرْضِ مَرَحًا إِنَّكَ لَنْ تَخْرِقَ الْأَرْضَ وَلَنْ تَبْلُغَ الْجِبَالَ طُولًا

**«Җирдә масаеп йөрмә. Һичшиксез, син** (авырлыгың һәм көчең белән) **җирне яра алмассың, биеклектә тауларга ирешә алмассың!»** («әл-Исра»).

Кешегә кол булу омтылышы хас. Бу уңайдан, йә нәфес омтылышларына, ягъни дөньяви мәнфәгатьләргә, яисә Раббысына кол булачак. Раббысына лаеклы кол була белү өчен нәфесне йөгәнли белергә кирәк. Моның өчен Әләст Бәзмидә бирелгән: «Әйе, Син безнең Раббыбыз!» – дигән антка тугры калу зарур.

Җан Раббысы белән бу килешүне төзегәндә һәрнәрсә ап-ачык була. Ул фәрештәләрне, илаһи олуглыкны яхшы күрә. Ләкин ант биргән бу җан, хәдиси-шәрифтә әйтелгәнчә, ана карынына 120 нче көндә иңеп, биш тойгының әсире була. Нәфес каршылыгына очрый. Нәфислектән тупаслыкка төренеп каплана. Ләкин аңа бу тупаслыктан котылуның юлы да күрсәтелә. Кеше бу биш тойгысын Аллаһның шәфкате белән үзенә насыйп ителгән рухи сәләтләре ярдәмендә һәм Ул теләгән юнәлештә пакьләп, нәфес киртәсен узган була. Биш тойгының туры юлга керүе бары тик калебнең чистарынуы һәм нәфеснең пакьләнүе белән генә мөмкин. Моның ахырында тупаслык кими, нәфислек арта һәм күңел хакыйкатьләрне кабул итә алырлык хәлгә килә.

فَإِذَا سَوَّيْتُهُ وَنَفَخْتُ فِيهِ مِنْ رُوحِي

**«**(Адәмне) **төзек бер хәлгә китергәч һәм рухымнан аның эченә өргәч!»** – дип, аятьтә («әл-Хиҗер», 29) тасвирланган җан – әмер галәменнән килгән солтани рух ул. Җан фани булган гәүдәнең эченә керә. Хәзрәти Мәүләна Җәләлетдин Руми солтани рухның гәүдә эчендә югалмавы һәм аңа хаким булуы турында шушы мисалны китерә:

«Әйрән эчендәге май ничек яшерен һәм күренмәс бер хәлдә булса, гәүдә эчендәге җан да шулай».

«Майның барлыкка килүе өчен әйрәннең түгелүе кирәк».

«Нәкъ шуның кебек, солтани рухның да, тәнне контрольгә алыр өчен, көрәшүе, үз-үзен тыеп торуы һәм берникадәр мәхрүмлекләргә сабыр итүе шарт».

Тупаслыктан, ягъни түбән дөнья ләззәтләреннән котылып, нәфислеккә ирешер өчен, калебнең илаһи тойгылар белән тулган булуы зарур. Югыйсә илаһи гыйлемгә ирешү мөмкин түгел. Мәрхүм шагыйрь Нәҗип Фазыл бу калеб турындагы хакыйкатьне дога-ялвару рәвешендә бик матур тасвирлаган:

«Миндә – кыенлык, Синдә – латыйфлык...
Аллаһым, гафу ит!

Латыйфлыктан гафу көтә тупаслык...
Аллаһым, гафу ит!

Иттән һәм сөяктән кыяфәт...
Аллаһым, гафу ит!»

Аллаһ Тәгалә аяти кәримәләрдә әйтә:

قَدْ أَفْلَحَ مَنْ تَزَكَّى. وَذَكَرَ اسْمَ رَبِّهِ فَصَلَّى

**«**(Нәфес әшәкелекләреннән) **арынган, Раббысының исемен зикер иткән һәм шуннан соң намаз укыган кеше уңышка ирешер»** («әл-Әгъла», 14–15).

وَالشَّمْسِ وَضُحيهَا. وَالْقَمَرِ إِذَا تَليهَا. وَالنَّهَارِ إِذَا جَلّيهَا. وَاللَّيْلِ إِذَا يَغْشيهَا.
وَالسَّمَاءِ وَمَا بَنيهَا. وَالْأَرْضِ وَمَا طَحيهَا. وَنَفْسٍ وَمَا سَوّيهَا.
فَأَلْهَمَهَا فُجُورَهَا وَتَقْويهَا. قَدْ أَفْلَحَ مَنْ زَكَّيهَا. وَقَدْ خَابَ مَنْ دَسّيهَا

**«Кояш һәм аның балкышы белән ант итәмен! Аңа ияргән ай белән дә! Аны чагылдырган чактагы көн белән! Аны каплаган чактагы төн белән! Күк һәм аны бина итүче белән! Җир һәм аны түшәүче белән! Җан һәм аны төзек кылучы белән! Һәм аның күңеленә бозыклыкны һәм тәкъвалыкны салучы. Аны арындырган кеше уңышка ирешкән. Аны яшергән** (начарлыкларга күмгән) **кеше зарар күргән»** («әш-Шәмс», 1–10).

Диннең максаты – Хак Тәгаләгә лаеклы рәвештә кол булачак, күркәм, нәфис, сизгер һәм гыйлемле кеше тәрбияләү. Бу камиллеккә бары тик фикерләү һәм гыйлемгә хөрмәт белән карап югары дәрәҗәләргә күтәрелүчеләр генә ирешә алачак. Җәнабел-Хак камил иман ияләрен шулай тасвирлый:

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ الَّذِينَ إِذَا ذُكِرَ اللهُ وَجِلَتْ قُلُوبُهُمْ
وَإِذَا تُلِيَتْ عَلَيْهِمْ آيَاتُهُ زَادَتْهُمْ إِيمَانًا وَعَلَى رَبِّهِمْ يَتَوَكَّلُونَ

**«Инанучылар – Аллаһ искә алынган чакта йөрәкләре курку белән тулучылар, аларга Аның аятьләре укылган чакта, аларның иманнары артыр, һәм алар Раббыларына гына тәвәккәл итәрләр»** («әл-Әнфәл», 2).

الَّذِينَ إِذَا ذُكِرَ اللهُ وَجِلَتْ قُلُوبُهُمْ وَالصَّابِرِينَ عَلَى
مَا أَصَابَهُمْ وَالْمُقِيمِي الصَّلوةِ وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنْفِقُونَ

**«**(Аллаһка күңел белән баглылар ул)**, Аллаһ искә алынганда, кемнәрнең күңелләре курку белән тула, башларына килгән нәрсәләргә сабыр итәләр һәм намазны укыйлар, ризык буларак биргәннәребездән сарыф итәләр»** («әл-Хаж», 35).

Калеб Аллаһка мәхәббәт белән тулса, һәр гамәлнең гомуми һәм ахыргы максаты илаһи ризалыкка ирешү булыр. Кеше үзенең яратылыш хикмәтенә, фани дөньяның һәм Коръәннең хакыйкатенә тугры юл ала башлар. Нәфислеккә ирешмәгән, гафил һәм хаста җанлы колларны исә Аллаһ Җәллә Җәләлүһү сөймәс. Аяти кәримәдә әйтелә:

فَوَيْلٌ لِلْقَاسِيَةِ قُلُوبُهُمْ مِنْ ذِكْرِ اللهِ أُولَئِكَ فِي ضَلَالٍ مُبِينٍ

**«Аллаһның зикеренә** (карата йөрәкләре) **каты булганнарга ни үкенеч! Алар ап-ачык бер адашу эчендә»** («әз-Зүмәр», 22).

Аятьтә зикердән читләшкән кешенең кешелек дәрәҗәсе һәм бәхетен саклый алмавы, ягъни «әхсәни-тәкъвим» булу хосусиятенә ирешә алмавы белдерелә.

Нәфес бөтен дөньяви ләззәтләрне үзендә тупларга тырыша. Әмма нәфесне пакьләү нәтиҗәсендә калебне болардан арындырырга мөмкин. Мондый рухи тәрбия булмаган очракта, кеше нәфесенең колына әверелә. Аяти кәримәдә әйтелә:

أَرَأَيْتَ مَنِ اتَّخَذَ إِلَهَهُ هَوَاهُ أَفَأَنْتَ تَكُونُ عَلَيْهِ وَكِيلًا

**«**(Рәсүлем!) **Яман теләген** (нәфсани теләкләрен) **үз илаһы иткән кешене күрдеңме? Әллә аңа син яклаучы буласыңмы?** (син аны яклап та коткара алмассың)**»** («әл-Фуркан», 43).

Вәхигә түгел, үзләренең һәвәсләренә буйсынганнарның хәле аяти кәримәдә «һәвәсен илаһ иткән» дигән тәгъбир белән тасвирлануы игътибарны

җәлеп итә. Коръәни-Кәримдә «һәвәс» сүзе гыйлемнең, ягъни Аллаһ Тәгалә биргән белемнәрнең капма-каршысын белдерә. Аяти кәримәдә болай диелә:

وَلَئِنِ اتَّبَعْتَ أَهْوَاءَهُمْ مِنْ بَعْدِ مَا جَاءَكَ مِنَ الْعِلْمِ إِنَّكَ إِذًا لَمِنَ الظَّالِمِينَ

**«Әгәр сиңа гыйлем килгәннән соң, аларның теләкләренә иярсәң, син, һичшиксез, ул вакытта золым итүчеләрдән булырсың»** («әл-Бәкара»).

Коръәни-Кәримдә «һәвәс»кә буйсыну ялгышуның иң беренчел һәм мөһим сәбәбе буларак искә алына. Дини мәсьәләләрдә һәвәскә, ягъни нәфеснең теләкләренә буйсынучыларның тугры юлдан язачаклары, Аллаһ юлыннан читләшәчәкләре шиксез.

Ибне Каййим әл-Җәвзийя, кешегә сынау буларак бирелгән нәфеснең хосусиятләрен ачыклап, болай ди:

«Сөбханаллаһ! Нәфестә Иблиснең тәкәбберлеге, Кабилнең көнчелеге, Гад кавеменең ярсулыгы, Сәмуд кавеменең азгынлыгы, Нәмрудның батырлыгы, Фиргавеннең тотнаксызлыгы һәм чиктән ашуы, Карунның золым һәм явызлыгы, Хаманның түбәнлеге, Бәлгамның һәвәсе, Әсхәбе-Сәбтнең хәйләкәрлеге, Вәлид ибне Мугирәнең үзсүзлеге һәм Әбү Җәһилнең наданлыгы бар.

Шулай ук кеше нәфесендә хайван сыйфатлары дә чагыла. Мәсәлән, карганың комсызлыгы, этнең артык күп ашавы һәм убырлыгы, тависның үз-үзеннән мөкиббән булуы, май коңгызының әшәкелеге, кәлтәнең буйсынмаучанлыгы, дөянең нәфрәте, юлбарысның кискенлеге, арысланның куркусызлыгы, тычканның әхлаксызлыгы, еланның түбәнлеге, маймылның кирәксез һәм буш хәрәкәтләре, кырмысканың тупланучанлыгы, төлкенең хәйләкәрлеге, төн күбәләгенең җиңел хәрәкәтләре һәм сыртланның йокысы.

Ләкин үз-үзеңне тыю һәм көрәш, барлык шушы сыйфатларны төзәтеп, кешене начар холыктан коткара» (Ибни Каййим әл-Җәвзийя, «Әл-Фәваид», Бәйрут, 1986, 98 б.).

Нәфеснең тиешенчә тәрбияләү өчен, әңгәмә кору, үз-үзеңне тыю, көрәш һәм зикер кебек рухи тәрбия алымнарына ихтыяҗ бар.

Иман җәүһәренең үзәге калеб булган кебек, зикер җәүһәренең үзәге дә калеб булыр. Зикер телдән күңелгә күчкәч, хакыйкый кол булу башлана, нәфесне йөгәнләү юлына керелгән була. Зикерне даими кылу нәтиҗәсендә аның хикмәте зикер итүчене тулаем биләп ала. Калеб Җәнабел-Хактан башка һәрнәрсәне оныта. Кол Раббысы белән бербөтен була. Ихсан халәтенә ирешә. Кол булуын һәм гыйбадәтен Раббысын күргән кебек дәвам иттерә.

**Хәзрәти Адәм белән Хәүва анабызның гафу ителүе**

Шайтанның котыртуы аркасында Җәнабел-Хакның әмеренә буйсынмаган Адәм галәйһиссәләм белән Хәүва анабыз, җәннәттән чыгарылып, бу дөньяга җибәрелә. Хәзрәти Адәм фәрештәләр тарафыннан Һиндстанның көньягындагы Цейлон утравына, ә Хәүва анабыз исә Кызыл диңгез буена – Җиддә шәһәре урнашкан җиргә төшерелә. Шул сәбәпле бик озак вакыт алар бер-берләреннән аерылган килеш яши. Адәм галәйһиссәләм белән Хәүва анабыз тәүбә кылып, гафу сорауны туктатмыйлар. Ләкин һаман да гафу ителмиләр. Ниһаять:

رَبَّنَا ظَلَمْنَا أَنْفُسَنَا وَإِنْ لَمْ تَغْفِرْ لَنَا وَتَرْحَمْنَا لَنَكُونَنَّ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«...Әй Раббыбыз! Без үзебезгә үзебез золым иттек. Әгәр безне гафу итмәсәң һәм кызганмасаң, һичшиксез, зыян итүчеләрдән булырбыз»**, – дип дога кылалар («әл-Әгъраф», 23). Риваятьләргә күрә, Галәмнәр даны булган Яралтучыга һаман да ялваруларын дәвам иттерәләр. Нәтиҗәдә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең руханиятенә сыенып, Аның бәрәкәте белән илаһи гафу алу насыйп була. Хәдиси-шәрифтә бу хакта болай бәян кылына:

*«Адәм галәйһиссәләм, җәннәттән чыгарылуына сәбәп булган хата эшләгәнен, ялгышуын аңлап:*

*«Йә Раббы! Мөхәммәд хакы өчен Синнән мине гафу итүеңне сорыйм», – ди. Аллаһ Тәгалә:*

*«Әй Адәм! Әле аны яралтмаган килеш*[49] *Мөхәммәдне каян белдең?» – дип сорый.*

*Адәм галәйһиссәләм:*

*«Йә Раббы! Син мине яралтып, миңа җан өргән вакытта башымны күтәрдем дә, Гарешнең баганаларына "Лә иләһә илләллаһ, Мухәммәдүр-Рәсүлүллаһ" дигән җөмләнең язылганын күрдем. Шунда аңладым: Син Үз исемең янына ратылганнарның бары тик иң сөеклесен генә өстәрсең!» – диде.*

*Шуннан соң Аллаһ Тәгалә:*

*«"Дөрес әйтәсең, әй Адәм! Чыннан да, ул Минем өчен мәхлукларның иң сөеклесе. Аның хакы өчен Миңа дога кыл. (Шулай дога кылганга күрә,) Мин дә*

49. Мәңгелектә бары тик Үзе генә булган Җәнабел-Хак, кешеләр һәм җеннәрнең аң-зиһен дәрәҗәсенә карап, Аны тануларын максат итә, ягъни үзеннән гайре булган һәрнәрсәне Ул яралта. Иң әүвәл «Мөхәммәд Нуры» бар ителә. Шуңа күрә Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Адәм җан белән тән арасында булганда, мин пәйгамбәр идем», – дип әйткән (Тирмизи, «Мәнакыйб», 1). Шул сәбәпле Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең җәүһәре дигәнне белдергән Мөхәммәд Нурының яратылышта беренче булганга күрә дә, гәүдәгә төрендерелеп вәкил итеп җибәрелгән пәйгамбәрләр чылбырында ул иң соңгысы. Югарыдагы гыйбарәдә Мөхәммәд Нуры түгел, кеше сыйфатында җибәрелгән «Мөхәммәд заты» күздә тотыла.

*сине гафу иттем. Әгәр Мөхәммәд булмаса, сине яралтмаган булыр идем!" – ди»* (Хаким, «Мүстәдрәк», II, 672).

Адәм галәйһиссәләм, Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең илаһи юнәлештәге кадерен һәм абруен истә тотып, ниһаять, Җәнабел-Хактан Аның хөрмәтенә гафу ителүен сорагач, бу теләк кабул ителә һәм Аллаһ Тәгалә, Мәккә тарафына юл күрсәтү өчен, бер фәрештәгә йөкләмә бирә. Бу дога бәрәкәте белән Җиддәдә яшәгән Хәүва анабыз да, башка бер фәрештә җитәкчелегендә Адәм галәйһиссәләм дә туры юлга чыгарыла һәм Зөлхиҗҗәнең тугызында, Гарәфә көненең икенде вакытында алар Гарәфәттә очраша, күз яшьләренә буыла-буыла яңадан Раббыларыннан гафу сорыйлар.

Хәзрәти Адәм белән Хәзрәти Хәүваның бер-берсенә булган мәхәббәтләре һәм тартылулары, Хәүваның башка төрле бер ыругдан түгел, ә Хәзрәти Адәмнән яратылган булуына нигезләнә.

Мәрхәмәте һәм рәхмәте чиксез булган Җәнабел-Хак аларның догаларын кабул иткән кебек, аларның нәселеннән булып, кыяматкә кадәр һәр ел бер үк көн һәм сәгатьтә Гарәфәткә килеп гафу сораучыларны да кичерә. Хаҗиларның Гарәфә көнне Гарәфәт тавында тәүбә-истигъфар кылуының хикмәте әнә шунда.

### Җир йөзендә беренче җинаять

Бу очрашудан соң Адәм галәйһиссәләм белән Хәүва анабыз, Аллаһның әмере белән, бүгенге Мәккә шәһәре урнашкан җирдә төпләнеп яшәп калалар. Шуңа күрә дә Мәккә шәһәрен тагын Үммүл-Кура, ягъни яшәү урыннарының үзәге дип тә йөртәләр. Нәкъ шушы урында кешеләрнең исәбе күбәя башлый. Кешеләрнең шулкадәр тиз артуының хикмәте Хәүва анабызның берьюлы берничә бала табуына бәйле. Бер йөклелек нәтиҗәсендә туган балалар кардәш булып, аларга бер-берләре белән никахлашу хәрәм кылына. Ләкин алар башка йөклелектән туганнар белән өйләнешә алган.

Кабил үзе белән бер йөклелектән һәм бер үк вакытта туган кыз кардәшенә өйләнергә тели. Хабил исә моның шәригатькә туры килмәве, башка вакытта туган кыз кардәшләреннән берсенә өйләнергә кирәклеге турында кисәтә. Кабил, бу кисәтүгә игътибар итмичә, һаман да үз гамәлләренең дөрес булуы фикерендә нык тора. Моңа каршы Хабил, бу очракта кемнең дөрес юлда булуын ачыклау өчен, кардәшенә Аллаһка атап берәр корбан чалдырырга тәкъдим итә.

Ул вакытларда корбан, һәркемнең мәсләгенә күрә, кулында булган малдан бирелгән. Корбан итеп бирелгән бу нәрсәләр бер тау башына куелган, бераз вакыт узганнан соң барып караганда, корбан, күктән иңгән ут тарафыннан яндырылып, юкка чыгарылган була, шул очракта Җәнабел-Хак тарафыннан кабул ителгән булып саналган.

Хабилнең сарык көтүе була. Корбан чалу өчен, ул шул сарыклардан иң симез һәм күркәм кыяфәтлесен сайлап ала. Кабил исә игенчелек белән шөгыльләнә. Ул бер бәйләм сыйфатсыз бодайны корбан итәргә була.

Бераз вакыт узганнан соң, Хабил белән Кабил үзләре китергән корбаннарын барып карарга юлга кузгала. Хабилнең корбан итеп китергән сарыгы кабул ителгән, ә Кабилнең сыйфатсыз бодай бәйләме исә шул килеш калган (Ибне Сагъд, I, 36). Кабил моңа бик нык ачулана һәм аяти-каримәдә әйтелгән рәвештә, кардәше Хабилне үтерә.[50]

وَاتْلُ عَلَيْهِمْ نَبَأَ ابْنَيْ آدَمَ بِالْحَقِّ إِذْ قَرَّبَا قُرْبَانًا فَتُقُبِّلَ مِنْ أَحَدِهِمَا وَلَمْ يُتَقَبَّلْ
مِنَ الْآخَرِ قَالَ لَأَقْتُلَنَّكَ قَالَ إِنَّمَا يَتَقَبَّلُ اللّٰهُ مِنَ الْمُتَّقِينَ. لَئِنْ بَسَطْتَ إِلَيَّ يَدَكَ
لِتَقْتُلَنِي مَا أَنَا بِبَاسِطٍ يَدِيَ إِلَيْكَ لِأَقْتُلَكَ إِنِّي أَخَافُ اللّٰهَ رَبَّ الْعَالَمِينَ. إِنِّي أُرِيدُ أَنْ
تَبُوءَ بِإِثْمِي وَإِثْمِكَ فَتَكُونَ مِنْ أَصْحَابِ النَّارِ وَذٰلِكَ جَزَاءُ الظَّالِمِينَ. فَطَوَّعَتْ لَهُ
نَفْسُهُ قَتْلَ أَخِيهِ فَقَتَلَهُ فَأَصْبَحَ مِنَ الْخَاسِرِينَ. فَبَعَثَ اللّٰهُ غُرَابًا يَبْحَثُ فِي الْأَرْضِ
لِيُرِيَهُ كَيْفَ يُوَارِي سَوْءَةَ أَخِيهِ قَالَ يَا وَيْلَتَا أَعَجَزْتُ أَنْ أَكُونَ مِثْلَ
هٰذَا الْغُرَابِ فَأُوَارِيَ سَوْءَةَ أَخِي فَأَصْبَحَ مِنَ النَّادِمِينَ

**«Аларга Адәмнең ике улының хәбәрен хак белән укы. Менә ул икәү берәр корбан тәкъдим иттеләр; аларның берсеннән** (Хабилдән) **кабул ителде, икенчесеннән исә** (Кабилдән) **кабул ителмәде.**

---

50. Монда ике мәсьәлә бар. Беренчесе « وَلَا تَزِرُ وَازِرَةٌ وِزْرَ اُخْرٰى » – «...Һичбер гөнаһкяр башка берәүнең гөнаһысы өчен җаваплы булмас...» («әл-Исра», 15) дип боерылган хәлдә, үтерелгән кешенең гөнаһы аңа ничек йөкләнә? Бу мәсьәлә берничә төрле аңлатыла. Бер хәдис-шәрифтә: «Бер-берсе белән талашкан ике кешенең сөйләгәннәре золымга илтә торган чикне узганчыга кадәр башлаган кешенеке була», — диелә (Мөслим, «Бирр», 69). Ягъни мәзлум, билгеле бер чикне узып, ялгышуын дәвам иттермәсә, беренче башлаган кеше нәкъ шушы үз гөнаһы өчен дә, гаугага сәбәпче булганга күрә, иптәшенең шундый ук гөнаһы өчен дә җаваплы булыр. Бу очракта «минем гөнаһым», дию, әгәр сиңа каршылык күрсәтер өчен кул сузсам, кылачак гөнаһым шул ук булыр дигән сүз. Шул хәлдә берсе чикне узып, икенчесе дә кул сузып, нәтиҗәдә икесе дә үлсә, башлаган кеше ике җинаять, икенчесе бер җинаять кылган була. Әгәр икенчесе каршылык күрсәтмәсә, шушы бер җинаятьтән дә котылган була. Ләкин катил һаман да ике җинаять кылган һәм ике гөнаһ өчен җаваплы була: берсе – мәзлумне үтергән өчен, икенчесе – үзен җәзага лаеклы итеп, утка ташлау җинаяте өчен. Моннан тыш, «минем гөнаһым» дигән сүз «мине үтерү гөнаһы», «синең гөнаһың» да «элегрәк кылган гөнаһларың» дигәнне аңлата.

Икенче төрле караш. Кешенең Аллаһка каршы баш күтәрергә теләве рөхсәт ителмәгән кебек, башка берәүнең баш күтәрүен теләве дә тыела. Бу очракта мондый тәкъва кешенең башка берәүнең ике җинаять кылуын теләве ничек рөхсәт ителсен инде? Бу сорауга ике төрле җавап бар. Беренчесе: бу сүзнең асыл максаты башка кешенең гөнаһка керүен теләү түгел, үзенең дә, аның да гөнаһка кермәвен теләү, гөнаһтан саклаучы берәр нәсыйхәт бирү. Икенчесе: баш күтәрү рөхсәт ителмәсә дә, баш күтәрүченең җәзаландырылуын теләү рөхсәт ителә. Бу уңайдан «мин гөнаһ кылырга теләмим, син үз дигәнеңдә торасың, алайса мин Аллаһтан синең җәзалануыңны сорыйм», дигән мәгънә дә килеп чыгарга мөмкин. Фәкать беренчесе күпкә ятышлырак (Әлмалылы, III, 1654).

**Ул** (Корбаны кабул ителмәгән кардәше, көнләшеп)**: «Мин сине, һичшиксез, үтерәчәкмен», – диде.**

**Ул исә әйтте: «Аллаһ тәкъвалык ияләреннән генә кабул итә. Әгәр син мине үтерергә дип кулыңны сузсаң да, мин сине үтерергә дип кулымны сузмам. Чөнки, һичшиксез, мин галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһтан куркамын. Мин синең үз гөнаһың белән минем гөнаһымны да йөкләп, Ут әһеле булуыңны телим. Бу – залимнәрнең җәзасы».**

**Нәфесе аны** (Кабилне) **кардәшен үтерүгә этәрде, һәм ул аны үтерде, һәм ул югалтучылардан булды. Шуннан кардәшенең гәүдәсен ничек каплауны күрсәтер өчен, Аллаһ аңа җирне казып торган бер карга җибәрде.**

**«Ул** (үтерүче)**: ”Ни үкенеч миңа! Мин шушы карга кебек тә була алмыйм һәм кардәшемнең гәүдәсен дә каплый алмыйммыни?” – диде. Һәм ул үкенгәннәрдән булды»** («әл-Маидә», 27–31).

Бу кыйссада вәхинең нуры белән яктыртылган акыл һәм нәфеснең хакимлегеннән котыла алмыйча, бу нурдан мәхрүм калган акыл чагыштырыла һәм болардан килеп чыккан нәтиҗәнең җанлы мисалы тасвирлана. Акылның вәхи эчендә бәһасе бар. Вәхигә хезмәт иткән һәм аны юл күрсәтүче итеп кабул иткән акыл хикмәтләргә юлыгыр. Вәхинең юл күрсәтүеннән мәхрүм булган акыл исә кешене нәфеснең афәтләреннән саклый алмас. Акыл һәртөрле максат өчен кулланылырга мөмкин булган үткен пычак кебек. Теләгән кеше аның белән икмәк кисәр, теләгәне аның белән җинаять кылыр. Шулай итеп, Кабилнең акылы, вәхидә әйтелгәннәргә каршылык иткән өчен, үзен ялгышка этәргән һәм ахирәттәге киләчәген җимергән.

Тәкъвалык һәм ихласлылыктан мәхрүм булган кешеләрдә акыл үзләренә дә, башкаларга да каршы шул кешенең золымын арттыра. Кабил мисалындагы кебек, хәтта кардәшен үтерүгә үк барып җитәргә мөмкин. Акыл нигъмәтен вәхи кушкан юнәлештә кулланып, Кабилгә нәсыйхәттә булган Хабил, ихлас кол булганга күрә, күңелендәге Аллаһтан курку хисе белән эш иткән.

Көнчелек һәм хөсетлек хасталыгы белән авыручылар, үзләренә тиешле нигъмәтне күрмичә, башкалар кулындагы нигъмәтләргә күз сала. Нәфеснең начар сыйфатларыннан булган көнчелек һәм хөсетлек кемне үз канаты астына алса, аңа төрле яманлыклар эшләттерә. Хәтта бу кеше кардәшен үтерүдән дә тайчынмый. Хөсетле һәм көнче кешеләр илаһи тәкъдиргә риза булмый. Нәтиҗәдә, дөньяда түбәнчелеккә төшеп һәм рисвай булып, олы вөҗдан газабына дучар ителәләр. Алар ахирәттә дә үкенечле газапка юлыгачаклар. Бу хасталыкның чарасы – нәфесне яңадан тәрбияләү һәм пакьләү, мәҗбүр итүче нәфестән ышанычлы нәфескә ирешү һәм, бигрәк тә, Аллаһның биргәннәренә риза булу.

Кабил белән Хабилнең кешелек сыйфатларында фәрештә белән шайтан арасындагы капма-каршылыкны хәтерләткән аерма бар. Кабил шайтан кебек үзенең кимчелеген кардәшендә эзли. Хабил, фәрештә кебек эш итеп, нәфес тозагына эләкми, абруен югалтудан һәм үлем янавыннан курыкмый, бары тик Аллаһтан курку хисе белән гамәл кыла. Ягъни аларның берсе шайтан кебек хата кылуда нык тора, икенчесе исә Аллаһка юнәлә.

Коръәни-Кәрим берәр кешенең хаксызга үтерелүенең никадәр зур җинаять икәнлеген һәм берәр кешене үлемнән саклап калуның никадәр хәерле гамәл булуын түбәндәгечә аңлата:

مِنْ أَجْلِ ذٰلِكَ كَتَبْنَا عَلَى بَنِي إِسْرَائِيلَ أَنَّهُ مَنْ قَتَلَ نَفْسًا بِغَيْرِ نَفْسٍ أَوْ فَسَادٍ فِي الْأَرْضِ فَكَأَنَّمَا قَتَلَ النَّاسَ جَمِيعًا وَمَنْ أَحْيَاهَا فَكَأَنَّمَا أَحْيَا النَّاسَ جَمِيعًا

**«Шул сәбәпле, Без Исраил улларына әмер иттек: кем дә кем бер җан өчен яки җирдә бозыклык булмыйча, бер җанны үтерсә, гүя бөтен кешене дә үтергән кебек булыр. Кем дә кем аны терелтсә, гүя бөтен кешеләрне терелткән кебек булыр…»** («әл-Маидә», 32).

Кешелек тарихында беренче тапкыр адәм нәселен үтерү һәм туганыңның канын кою вакыйгасы турында Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

*«Явызлык белән үтерелгән һәр кеше каныннан (үтерү гөнаһыннан) Адәмнең беренче улына да, һичшиксез, өлеш чыгарыла, чөнки ул беренче тапкыр кеше үтерү юлын ачкан»* (Бохари, «Әнбия», 1; Мөслим, «Касамә», 27).

Шулай ул Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый сүзләре дә тапшырыла:

*«Исламда яхшы, игелекле гамәлгә юл салган (шундый эшне башлап җибәргән) затка савап языла. Шул юлдан баручыларның савабыннан да аңа өлеш чыгарыла, ләкин аларның савабы һич кимемәс. Ә кем дә булса исламда начар гамәлгә юл салса, бу кешегә гөнаһ языла. Шул юлдан баручыларның гөнаһыннан да аңа өлеш чыгарыла. Ләкин аларның гөнаһы һич кимемәс»* (Мөслим, «Зәкят», 69; Нәсаи, «Зәкят», 64).

Бу хәдис-шәриф тә шуны раслый: кем дә булса яхшылыкка юл күрсәтсә, үзеннән соң дәвам иткән ул игелектән, ә кем дә булса берәр әшәкелек китереп чыгарса, үзеннән соң барлыкка килеп торган ул әшәкелектән өлеш алыр.

Имам Газалинең «Ихья» исемле хезмәтендә бик күркәм сүзләр әйтелә:

وَطُوبَى لِمَنْ مَاتَ وَمَاتَتْ مَعَهُ ذُنُوبُهُ وَالْوَيْلُ الطَّوِيلُ لِمَنْ يَمُوتُ وَتَبْقَى ذُنُوبُهُ مِائَتَى سَنَةٍ

«Үлгән һәм үзе белән бергә гөнаһлары да үлгән затка нинди бәхет! Үзе үлсә дә, гөнаһлары йөзләрчә ел дәвам иткән бәхетсезгә исә никадәр кайгы-хәсрәт!»

Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Алга таба шундый фетнәләр кубачак ки, ул вакытта утырып торганнар аякта басып торганнардан, аякта басып торучылар йөрүчеләрдән, ә йөреп торучылар йөгерүчеләрдән хәерлерәк булачак»*, – дип әйтә.

Сәгъд ибне Әби Вәккас радыйаллаһу ганһе:

«Йә Рәсүлүллаһ! Берәр кеше өемә кереп, үтерер өчен миңа кул сузса, нишләргә киңәш бирәсең?» – дигәч, Хәзрәти Пәйгамбәр галәйһис-саләтү вәссәләәм:

*«Адәмнең улы (Хабил) кебек бул!»* – дип белдерә (Тирмизи, «Фитән», 29/2194).

Ислам дине биш нәрсәне сакларга һәм якларга куша. Болар – җан, акыл, дин, нәсел һәм мал. Боларга карата теләсә нинди һөҗүм очрагында кеше кирәкле каршылык күрсәтергә, көрәшергә тиеш. Ләкин бу көрәш вакытында динебез күрсәткән юлдан бару кирәк. Фәкать залимме яки мазлуммы (кыерсытылучы) булырга дигән сайлау алдында, Пәйгамбәребез киңәшенә колак салып, залимлеккә түгел, ә мазлум булуга өстенлек бирү зарур.

Һабил үтерелгәч, Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Адәм белән Хәүва янына Шис[51] галәйһиссәләмне җибәрә. «Шис» сүзе «Аллаһның бүләге, бүләк ителгән әйбер» дигән мәгънә белдерә. Хәзрәти Шис галәйһиссәләм Коръәни-Кәримдә исеме телгә алынмаган пәйгамбәрләрнең берсе булып тора, аңа 50 сәхифә иңдерелә. Үләр алдыннан Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм Шис галәйһиссәләмне үз янына чакыра да аңа көн һәм төннең сәгатьләрен аеру тәртибен, бу вакытларда кылынырга тиешле гыйбадәтләрне өйрәтә һәм җиргә туфан киләчәге турында хәбәр итә.

Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм җомга көнне вафат була, фәрештәләр килеп, аны юа, кәфенли һәм дәфен кыла. Риваятьләрдә Адәм галәйһиссәләмнең мең ел яки 930 ел яшәгәнлеге сөйләнә.

### Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм кыйссасыннан алынырга тиешле сабаклар

1. Кешене һәрдаим начарлыкка өндәүче һәм аның ачык дошманы – шайтанның мәкеренә каршы бик сак һәм игътибарлы булырга кирәк.

51. Башка чыганакларыбызда бу исем Шис рәвешендә телгә алына. Телебездә Шис рәвешендә әйтелеше җиңелрәк булганга һәм халык арасында шул исем белән танылганга, Шис рәвешендә язуга карар кылдык.

2. Кешене мәңгелек хәсрәткә илтәчәк тәкәбберлек, көнчелек, комсызлык, ашыгучанлык кебек тискәре сыйфатлардан котылу өчен, нәфесне тәрбияләү, йөрәкне пакьләү зарур.

3. Берәр гөнаһ гамәл эшләгәндә, Адәм галәйһиссәләм кебек, шундук тәүбә кылырга кирәк.

4. Һичбер хатабыз булмаса да, Аллаһның нигъмәтләре каршында лаеклы дәрәҗәдә шөкер итә алмавыбыз аркасында, әлеге гаҗизлегебезне тәүбә-истигъфарга юнәлтергә тиешбез.

5. Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм белән Хәзрәти Хәүва анабызның тыелган агачка кагылу вакыйгасыннан алынган нәтиҗәгә күрә, Аллаһ колларының гөнаһ эшләгәннән соң югалган рухи тынычлыклары, тәүбә кылганнан соң, кабат кире кайтарыла.

6. Хәзрәти Адәм кебек, догаларыбызда һәрдаим Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм исемен искә алу тиеш, шатлыклы һәм газаплы һәр мизгелдә аны телдән төшереп калдыру, калебтән алып ташлау тыела.

7. Хабил шикелле, солтани рухны нәфескә буйсындырмыйча һәрчак өстен куеп, күркәмлек, камиллек серен белер өчен тырышлык кую зарур.

8. Изге гамәл эшләүгә этәрүчеләрнең үзләреннән соң шул ук яхшылыкны эшләүчеләр әҗереннән өлеш алачагын, шул ук вакытта начарлыкка сәбәп булучыларның үзләреннән соң шул ук начарлыкны кылучылар гөнаһыннан өлеш алачагын һичкайчан хәтердән чыгарырга ярамый. Әнә шул рәвешле Хабил изгелеккә, Кабил исә начарлыкка юл сала.

9. Кеше хөрмәтле зат итеп яралтыла һәм аның мәхлукларның иң югары дәрәҗәлесе икәнлеге белдерелә.

**Йомгаклап, шундый нәтиҗә ясыйбыз – Хәзрәти Адәм:**

Беренче булып җәннәт һәм дөньялыкта яшәгән зат;.

Тәүге киенгән, капланган зат;

Тәүге онытучы;

Тәүге хаталанучы;

Тәүге тәүбә кылучы;

Тәүге пәйгамбәр була (Аңа 10 сәхифә иңдерелә);

Тәүхид өчен көрәшкән тәүге зат;

Бала югалту хәсрәтен тәүге тойган зат;

Тәүге сәлам бирүче;

Туфрак эшкәртүче тәүге зат;

Кыскасы, ул – беренче кеше була.

Галәйһиссәләм!..

# ТӘҮБӘ ҺӘМ ИСТИГЪФАР

Дөнья сынау мәйданы булганга күрә, кешеләрнең яхшылык яки начарлык юлын сайлау мөмкинлеге бар. Өндәү-үгетләү яки котырту нәтиҗәсендә бу теләкләрнең кайсы үстерелсә, кеше шәхесе шул юнәлештә формалаша.

Берәү һич мәҗбүр ителмичә, үз ихтыяры белән янындагы кешегә бер чынаяк су тәкъдим иткән очракта, ул кеше рәхмәт әйтергә бурычлы, әлеге күренеш әхлакый һәм намус бурычы буларак кабул ителә. Чынлыкта, әлеге чагыштыру безгә Җәнабел-Хакның хисапсыз нигъмәтләренә каршы никадәр рәхмәт һәм шөкер итү хисе белән яшәвебез тиешлеген күрсәтә. Димәк, холык-табигатендәге наданлык, шәһвәт, тәкәбберлек, горурлык, комсызлык, хөсет, исрафка бирелү һәм үпкәчеллек кебек тискәре сыйфатларга бирешеп, кыскасы, нәфескә буйсынып, кешенең илаһи нигъмәтләр каршында рәхмәтсез кылануы – ул яратылыштан ук ия булган хөрмәт-шәрәфенә тап төшерә торган олуг алдану.

Нәфес теләкләренә, шәһвәтенә җиңелгән һәм иманның бәрәкәтле яктысын югалткан вакытта, адәм баласы гөнаһларга тартыла башлый. Намусында әхлакый нигез какшаса, рухи тирәнлек һәм йомшак, нәзакәтле фикерләү дә югала. Кешенең туры, дөрес юлдан барырга тырышуында җитди зәгыйфьлек барлыкка килә. Гөнаһлар, матур җыр-көй кебек, нәфескә бик ошый һәм начар гамәлләр аларның авырлыгын сизмичә дә диярлек эшләнә.

Кешенең дөньялыкта гафиллек белән, игътибарсызлыгы аркасында кылган гөнаһлары аның кешелек дәрәҗәсен төшерә, шәхесенә зыян сала. Бу хәл җаннарның гөнаһ караңгылыгына батырылуына бер сәбәп була.

Хәлбуки, адәм баласы гөнаһсыз, саф күңелле, пакь булып дөньяга килә. Дин исә, бу табигый сафлыкны саклау өчен, Аллаһ тарафыннан кешегә бирелгән бер игелек һәм мәрхәмәт чагылышы булып тора. Димәк, кол бу ике бүләк ярдәмендә ваемсызлык пәрдәләрен ачып ташлый алса, кылган гаебенең авырлыгын бар күңеле белән тоя. Аның күңел төпкелендә сакланган фазыйләт хисләре уяна. Йөрәге бик зур үкенеч хисендә яна һәм бәндә яшьле күзләре белән Раббысына күңелен ача. Әнә шул йөрәк яну һәм үкенү тәүбә була да инде. Шуннан соң гафу сорау өчен Раббысына ачылган кул учлары һәм йөрәктән агылган ялварулы үтенечне «истигъфар» дип атыйлар.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү колының үкенеченнән, тәүбәсеннән, истигъфарыннан канәгать һәм риза булыр, чөнки Ул «Рахман» һәм «Рәхим»[52] кебек күркәм исем-сыйфатлар иясе.

إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ التَّوَّابِينَ وَيُحِبُّ الْمُتَطَهِّرِينَ

**«...Шуны яхшы белегез: Аллаһ тәүбә итүчеләрне һәм тәмам чистарынучыларны сөя»**, – диелә Коръәни-Кәримдә («әл-Бәкара», 222).

Аллаһ Тәгаләнең колларына карата шәфкать-мәрхәмәте ананың баласына карата мәрхәмәтеннән, һичшиксез, күпкә көчлерәк. Ул колларын газапларга теләми. Фәкать бәндә рәхмәтсез кыланса, үзсүзлелек белән золым-явызлык эшләвен дәвам итсә, җәзага лаек була. Рахман һәм Рәхим исемнәренең чагылышы буларак, Аллаһның рәхмәт-мәрхәмәте газабыннан күпкә артыграк. Чыннан да түбәндәге хәдис-шәрифтә бәндәләрнең тәүбә-истигъфар каршында Аллаһ Тәгаләнең ризалыгы һәм канәгатьлеге бик матур телгә алына:

*«Берәрегезнең тәүбә итүе сәбәпле Аллаһ Тәгалә тойган канәгатьлек, япа-ялгыз чүлдән барганда, ризыгы-эчемлекләре төялгән дөясе качып киткән, эзләве нәтиҗә бирмәгәч, дөяне табу өметен тәмам югалтып, бер агач күләгәсендә сузылып яткан, шул мизгелдә янына дөясенең килүен күреп, йөгәненә ябышкан һәм бик нык сөенеп, ни сөйләгәнен үзе дә ишетмичә:*

*«Аллаһым! Син – минем колым, ә мин – Синең Раббың», – дигән затның шатлыгыннан бик күпкә көчлерәк»* (Мөслим, «Тәүбә», 7; Тирмизи, «Кыямәт», 49).

Аллаһның рәхмәте һәрнәрсәне чолгап алган. Чыннан да, Җәнабел-Хак:

وَرَحْمَتِي وَسِعَتْ كُلَّ شَيْءٍ

**«...Рәхмәтем һәрнәрсәне каплап алган...»** – дип («әл-Әгъраф», 156), колларына карата мәрхәмәтенең чиксез киңлеге турында хәбәр итә. Әлеге хакыйкатьне раслап, Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә кодси хәдистә Хак Тәгаләнең: *«Рәхмәтем чыннан да газабымнан өстенрәк!»* – дигәнен белдерә (Бохари, «Тәүхид», 15).

Шуңа күрә бөтен пәйгамбәрләр өммәтләрен һәрдаим тәүбә-истигъфарга чакырган.

Пәйгамбәрләрдән кала, һичбер кеше, бәндәчел үзенчәлекләре сәбәпле, гөнаһсыз булмас, азмы-күпме гөнаһ гамәлләрдән берәү дә саклана алмас. Шуңа күрә Коръәни-Кәримдә гөнаһлардан арыну мәгънәсендәге сүз – «Тәүбә» исеме белән аталган мөстәкыйль сүрә урын алган. «Тәүбә» сүзе Коръәни-Кәримдә сиксән тапкырдан артыграк очрый. Аллаһ Тәгаләнең гөнаһларны

52. Рахман – «рәхмәте мул булган» мәгънәсендәге сыйфат фигыль формасы. Рәхим сүзе исә дәвамлылыкны белдерә һәм «рәхмәт итүче һәм рәхмәтен мәхлукларына ирештерүче» дигәнне аңлата.

кичерәчәген белдергән йөзләрчә сүздән, аерым алганда, «Гафур» исеме туксан ике мәртәбә, «Гаффар» исеме биш урында кабатлана, «Гафир» исем-шәрифе исә бер тапкыр искә алына. Болар барысы да тәүбәнең әһәмиятен һәм Җәнабел-Хак тарафыннан кабул ителәчәген күрсәтү белән бергә бәндәләрне тәүбә-истигъфарга чакыра.

Гөнаһның, хәтта ваемсызлыкның гаеп эш икәнен тануы Аллаһ колы өчен – гыйрфан, Раббысыннан гафу соравы исә намус бурычы булып тора. Гөнаһның гаеп эш икәнлеген таный алмау һәм аннан йөз чөерү кирәклеген аңламау (Алла сакласын) – йөрәкнең хис-тойгылардан бушап калуы һәм җәһәннәм сәфәре галәмәте ул. Аллаһ Тәгалә андый хәлгә төшүдән бик куркыныч кисәтә:

وَمَنْ لَمْ يَتُبْ فَأُولَئِكَ هُمُ الظَّالِمُونَ

**«...Кем дә кем тәүбә итмәсә, алар – золым итүчеләр!»** («әл-Хуҗурат», 11).

Хәдис-шәрифтә:

*«Кылган гөнаһларга үкенү тәүбә була. Гөнаһларына тәүбә иткән зат ул гөнаһны эшләмәгән кебек булыр»,* – диелә (Ибне Мәҗә, «Зүһд», 30; Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 161).

Бәндә бер ялгышлык эшләгән вакытта, Аллаһның гафу итәчәгенә алданып, соңарырга ярамый, шунда ук тәүбә җебенә ябышырга кирәк. Чөнки аяти кәримәдә тәүбә кабул ителсен өчен ашыгу кирәклеге анык белдерелә:

إِنَّمَا التَّوْبَةُ عَلَى اللَّهِ لِلَّذِينَ يَعْمَلُونَ السُّوءَ بِجَهَالَةٍ ثُمَّ يَتُوبُونَ مِنْ
قَرِيبٍ فَأُولَئِكَ يَتُوبُ اللَّهُ عَلَيْهِمْ وَكَانَ اللَّهُ عَلِيمًا حَكِيمًا

**«Начар бернәрсәне белмичә эшләгәннән соң, тиз арада тәүбә итүчеләрнең тәүбәсен Аллаһ Үзенә йөкләде. Аллаһ аларның тәүбәләрен кабул итә. Һичшиксез, Аллаһ – Галим** (белүче)**, Хәким** (һәр эше хикмәтле һәм карарлы булучы)**»** («ән-Ниса», 17).

Шайтанга алданып, тәүбәне соңартучыларның газаплы ахыры турында исә мондый хәбәр бирелә:

وَلَيْسَتِ التَّوْبَةُ لِلَّذِينَ يَعْمَلُونَ السَّيِّئَاتِ حَتَّى إِذَا حَضَرَ أَحَدَهُمُ الْمَوْتُ قَالَ إِنِّي
تُبْتُ الْآنَ وَلَا الَّذِينَ يَمُوتُونَ وَهُمْ كُفَّارٌ أُولَئِكَ أَعْتَدْنَا لَهُمْ عَذَابًا أَلِيمًا

**«Явызлык кылган, үлем килгәч: “Мин хәзер тәүбә иттем”, – дип әйткәннәргә ул тәүбә юк** (кабул ителми)**. Һәм кяфер булып үлгән кешеләргә дә. Әнә шулар өчен Без тилмерткеч бер газап әзерләдек»** («ән-Ниса», 18).

Кайбер галимнәребез аяти кәримәдәге бу илаһи кисәтү турында бәян кылганда, газаптан котылуның юлын күрсәтә:

«Үлем килгәнче, тәүбә итәргә ашыгыгыз!» (Мөнави, «Фәйзүл-Кадир», V, 65).

Тәүбә кабул ителсен өчен, тел белән «әстәгъфируллаһ» дип әйтү генә җитми. Бер үк вакытта ихлас йөрәктән чыккан үкенеч белән шундый ук хатаны кабатламаска карарлылык та зарур.

Хәзрәти Мәүләна Җәләлетдин Руми тәүбә таләп ителгән рухи халәтне түбәндәгечә аңлата:

«Үкенеч уты тулы күңел һәм яшьле күзләр белән тәүбә ит! Чөнки чәчәкләр кояшлы һәм дымлы җирләрдә ачыла!»

Тәүбә-истигъфар кешене һәм халыкларны иминлеккә илтә. Киләчәк бәла-газапларны юкка чыгара. Түбәндәге хәдис-шәриф мөэминнәрнең эш-гамәлләрен төзәтүдә бик зур әһәмияткә ия:

«Бер мөэмин Аллаһ газабының никадәр куәтле икәнен белсә, җәннәттән өметен өзәр иде! Кяферләр исә Аллаһның мәрхәмәтен никадәр киң икәнлеген белсәләр, җәннәткә керергә өмет итәрләр иде!» (Мөслим, «Тәүбә», 23).

Бу күзлектән караганда, һәр мөэмин «хәвеф һәм рәҗа», ягъни «курку белән өмет» арасында яшәргә тиеш. «Җәһәннәмгә бер генә кеше керәчәк!» дисәләр, «әллә мин микән?» дигән курку эчендә, «Җәннәткә бер генә кеше керәчәк!» дисәләр, янә «әллә мин микән?» дигән өмет эчендә булу кирәк.

Куркуның билгеле бер дәрәҗәләре булган кебек, мәхәббәткә дә төрле дәрәҗәләр хас. Гөнаһлы бәндәләр Аллаһ газабыннан курыкса, әүлиялар йөрәкләре яраткан Җәнабел-Хакны рәнҗетүдән һәм Аның мәхәббәтен югалтудан куркачак.

Шуны онытырга ярамый: хәтта пәйгамбәрләр дә хата җибәргән һәм бу кайгыдан тәүбә-истигъфарда гомер кичергәннәр. Шул рәвешле алар бәндәчел гаҗизлек хисен татып карый, чөнки абсолют бөеклек бары Аллаһка гына хас. Гаҗизлектән бары тик Аллаһ кына азат.

Иң беренче тәүбә итүче пәйгамбәр Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм була.

Хәүва анабыз белән бергә кылган тәүбәләре һәркемгә мәгълүм:

رَبَّنَا ظَلَمْنَا أَنْفُسَنَا وَإِنْ لَمْ تَغْفِرْ لَنَا وَتَرْحَمْنَا لَنَكُونَنَّ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«...И, Раббыбыз! Без үз-үзләребезгә золым иттек. Әгәр дә Син безне гафу итмәсәң һәм безгә мәрхәмәт итмәсәң, без зарар күргәннәрдән булырбыз»** («әл-Әгъраф», 23).

Бу дога алардан соң кыяматкәчә килеп китәчәк кешелек нәселенә иң күркәм истигъфар үрнәге булып тора.

Җәнабел-Хак, үзенең мәрхәмәтлелеге сәбәпле, колларын тәүбә-истигъфарга өндәгән һәм шул рәвешле аларны гафу итәчәге турында шатлыклы хәбәр җиткергән аятьләрендә болай дип әйтә:

إِلَّا مَنْ تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا فَأُولَئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَحِيمًا. وَمَنْ تَابَ وَعَمِلَ صَالِحًا فَإِنَّهُ يَتُوبُ إِلَى اللَّهِ مَتَابًا

**«Тик** (кылган начарлыкларыннан) **тәүбә иткән, иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр булмаса гына! Аларның начарлыкларын Аллаһ күркәм нәрсәләр белән** (гөнаһларын савапларга) **алмаштырачак. Аллаһ – Гафу итүче, Рәхимле. Кем дә кем тәүбә итсә һәм изге гамәл кылса, ул, чыннан да, бер кайту белән Аллаһка кайткан булыр»** («әл-Фуркан», 70–71).

وَالَّذِينَ إِذَا فَعَلُوا فَاحِشَةً أَوْ ظَلَمُوا أَنْفُسَهُمْ ذَكَرُوا اللَّهَ فَاسْتَغْفَرُوا لِذُنُوبِهِمْ وَمَنْ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلَّا اللَّهُ وَلَمْ يُصِرُّوا عَلَى مَا فَعَلُوا وَهُمْ يَعْلَمُونَ. أُولَئِكَ جَزَآؤُهُمْ مَغْفِرَةٌ مِنْ رَبِّهِمْ وَجَنَّاتٌ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا وَنِعْمَ أَجْرُ الْعَامِلِينَ.

**«Янә алар бик кабахәт бернәрсә эшләсә яки үзләренә золым китерсә, Аллаһны искә төшерәләр дә, гөнаһлары өчен ярлыкау сорыйлар. Гөнаһларны исә Аллаһтан башка кем гафу итә? Һәм алар, белә торып, гөнаһларын кабатлауда үҗәтлек күрсәтмиләр. Әнә шуларның әҗерләре – Раббыларыннан мәгъфирәт һәм алар мәңге калачак асларыннан елгалар аккан җәннәтләр. Гамәл кылучыларның савабы нинди яхшы!»** («Әли Гыймран», 135–136).

Аяти кәримәдә иманлы тормыш алып баручыларның гөнаһлы эшләрдә үҗәт түгеллегенә һәм шундук тәүбәгә килүенә басым ясала, чөнки мөэминнәр: «Үҗәтлек белән кылынганда, кече гөнаһлар кече генә булып калмыйча, зур гөнаһка әверелер, ә дәвамлы истигъфар кылганда исә, зур гөнаһлар кичерелеп, сөртеп ташланыр», – дигән хикмәтле хөкем кушканча эш йөртер. Аяти кәримәләрдә болай диелә:

أَلَمْ يَعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ هُوَ يَقْبَلُ التَّوْبَةَ عَنْ عِبَادِهِ وَيَأْخُذُ الصَّدَقَاتِ وَأَنَّ اللَّهَ هُوَ التَّوَّابُ الرَّحِيمُ

**«Алар Аллаһ колларыннан тәүбәне кабул иткәнен һәм сәдакаларын алганын һәм, һичшиксез, Аллаһның тәүбәләрне кабул итүче, Рәхимле икәнен белмиләрме әллә?»** («әт-Тәүбә», 104).

قُلْ مَا يَعْبَؤُا بِكُمْ رَبِّي لَوْلَا دُعَاؤُكُمْ

**«**(И Рәсүлем!) **Әйт: “Догагыз булмаса, Раббым сезгә нинди әһәмият бирсен?”»** («әл-Фуркан», 77).

Догада иң мөһиме – ихласлык, мәхәббәт һәм самимилек. Эчкерсез догалар мәхәббәт чагылышы булып тора. Югарыдагы аяти кәримәдә колның мәхәббәт белән кылган дога бәрабәренә әһәмияткә ия булуы белдерелә. Шунлыктан, тәүбәләр ихлас күңелдән әйтелергә тиеш. Изге Китапта мондый аяти кәримәләр дә бар:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا تُوبُوا إِلَى اللهِ تَوْبَةً نَصُوحًا عَسَى رَبُّكُمْ أَنْ يُكَفِّرَ عَنْكُمْ سَيِّئَاتِكُمْ

**«И иман китерүчеләр! Аллаһка ихлас бер тәүбә белән тәүбә итегез. Бәлки** (шулай эшләгән очракта)**, Раббыгыз начар эшләрегезне сезнең кичерер!..»** («әт-Тахрим», 8).

إِلَّا الَّذِينَ تَابُوا وَأَصْلَحُوا وَاعْتَصَمُوا بِاللَّهِ وَأَخْلَصُوا دِينَهُمْ لِلَّهِ فَأُولَئِكَ
مَعَ الْمُؤْمِنِينَ وَسَوْفَ يُؤْتِ اللَّهُ الْمُؤْمِنِينَ أَجْرًا عَظِيمًا

**«Фәкать тәүбә иткән, төзәткән, Аллаһка нык ябышкан һәм диннәрен Аллаһ өчен генә багышлаган кешеләрдән тыш. Әнә шулар** (чыннан да) **– мөэминнәр белән бергә. Аллаһ мөэминнәргә зур бер әҗер бирәчәк»** («ән-Ниса», 146).

وَاللَّهُ يُرِيدُ أَنْ يَتُوبَ عَلَيْكُمْ وَيُرِيدُ الَّذِينَ يَتَّبِعُونَ الشَّهَوَاتِ أَنْ تَمِيلُوا مَيْلاً عَظِيمًا

**«Аллаһ гөнаһларыгызны гафу итәргә тели. Шәһвәтләренә ияргән кешеләр исә сезнең бик адашып тайпылуыгызны телиләр»** («ән-Ниса», 27).

Илаһи әмерләргә каршы килү дигәнне белдергән гөнаһ эшләү халәтеннән бөтенләй тыелырга тырышкан очракта да, Җәнабел-Хак нигъмәтләренә лаеклы дәрәҗәдә шөкер итеп булмаганга күрә, һәркем тәүбә-истигъфарга мохтаҗ. Бу мәсьәләдәге бәндәчел гаҗизлек һәркемгә хас. Әгәр бәндә шөкер итә ала икән, бу да бер нигъмәт булып тора, шуңа күрә башка бер шөкерне таләп итә. Шул рәвешле бәндәнең шөкер итү бурычы һичкайчан бетми.

Хата-гамәлләрне гадәткә әйләндергән бәндәнең гөнаһлардан тулысынча тыелуы бик авыр. Кеше үзе белмичә, гөнаһ сазлыгына баса, үзенең гаҗизлеген тоеп, Раббысына сыена. Раббының бөеклеген һәм үзенең бик кечкенәлеген, мескенлеген тулысынча аңлавы әлеге ялвару-сыенуларның тирәнлегенә һәм эчтәлегенә бәйле. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

كُلُّ بَنِي آدَمَ خَطَّاءٌ. وَخَيْرُ الْخَطَّائِينَ التَّوَّابُونَ

*«Һәр кеше күп ялгышлар җибәрә ала. Фәкать хата җибәрүчеләрнең иң хәерлесе – күп тәүбә итүчеләре»*, – дип әйткән (Ибне Мәҗә, «Зүһд», 30/4251).

Ялгышлык җибәрүдән пәйгамбәрләр дә котылып кала алмый. Алар да вакыт-вакыт хата эшләр кылган һәм Раббыларына тәүбә-истигъфарлап ялварганнар. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисендә әйтә:

*«Кайчак йөрәгемнең пәрдәләнгән чагы була. Ләкин мин Аллаһка көн дә йөз тапкыр истигъфар кылам»* (Мөслим, «Зикер», 41; Әбү Давыт, «Витр», 26).

*«Валлаһи, мин көненә җитмеш тапкырдан артык, мине кичерүен сорап, Аллаһка тәүбә итәм»* (Бохари, «Дәгъват», 3; Тирмизи, «Тәфсир», 47; Ибне Мәҗә, «Әдәб», 57).

Ләкин Рәсүлүллаһның бу тәүбә-истигъфары күп очракта ниндидер бер ялгышлыгы аркасында түгел, ә Аллаһ Тәгаләгә тагын да якынрак булу һәм Аның ризалыгын алу теләге белән кылына. Пәйгамбәребез һәр мизгелдә рухи алгарышта булганга күрә, хәзерге хәле һәм дәрәҗәсенә күрә түбәнрәк булган әүвәлге хәле-урыны өчен истигъфар кыла. Ул өммәтенә төрле истигъфар рәвешен өйрәтеп калдырган. Аларның иң әһәмиятлесе – «сәййидүлистигъфар».

Шәддад ибне Әвес радыйаллаһу ганһедән риваять кылынганча, Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

*«Истигъфарның иң өстене – бәндәнең түбәндәгечә ялваруы:*

اَللَّهُمَّ أَنْتَ رَبِّي لَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ خَلَقْتَنِي وَأَنَا عَبْدُكَ، وَأَنَا عَلَى عَهْدِكَ وَوَعْدِكَ مَا اسْتَطَعْتُ، أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا صَنَعْتُ، أَبُوءُ لَكَ بِنِعْمَتِكَ عَلَيَّ وَأَبُوءُ لَكَ بِذَنْبِي فَاغْفِرْ لِي، فَإِنَّهُ لَا يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلَّا أَنْتَ

*«Аллаһым! Син – минем Раббым. Синнән башка табынырлык илаһ юк. Мине Син яраттың. Мин – Синең колың. Мәңгелектә Сиңа биргән сүземдә һәм вәгъдәмдә хәлемнән килгәнчә торам. Үзем эшләгән хата-кимчелекләр золымыннан Сиңа сыгынам. Миңа биргән нигъмәтләреңне Синең каршыңда рәхмәт хисе белән искә алам, гөнаһымны таныйм. Мине гафу ит, шиксез, гөнаһларны Синнән башка гафу итүче юк».*

Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм, сүзен дәвам итеп:

*«Кем дә кем әлеге сәййидүл-истигъфарны, аның савабына һәм фазыйләтенә бар йөрәге белән ышанып, көндез укыса һәм ул көнне кич җиткәнче үлеп китсә, җәннәт иясе булыр. Шулай ук кем дә кем, савабына һәм фазыйләтенә күңеленнән ышанып, төнлә укыса һәм таң атканчы үлеп китсә, җәннәт*

*иясе булыр»*, – дип әйтә (Бохари, «Дәгъват», 2, 16; Әбү Давыт, «Әдәб», 100–101; Тирмизи, «Дәгъват», 15; Нәсаи, «Истигазә», 57).

Хактан да, Җәнабел-Хакның нигъмәтләре шөкер-рәхмәтләребез һич җитмәслек дәрәҗәдә хисапсыз күп. Аяти кәримә бу сүзләрне раслый:

وَآتَاكُمْ مِنْ كُلِّ مَا سَأَلْتُمُوهُ وَإِنْ تَعُدُّوا نِعْمَتَ اللّٰهِ لَا تُحْصُوهَا إِنَّ الْإِنْسَانَ لَظَلُومٌ كَفَّارٌ

**«Ул сез сораган нәрсәләрдән бөтенесен сезгә бирде. Әгәр сез Аллаһның нигъмәтләрен саный башласагыз, аларны санап бетерә алмассыз. Һичшиксез, кеше – залим, нигъмәт кадерен белмәүче!»** («Ибраһим», 34).

Табигыйннәр арасында алдынгы гыйлем ияләренең берсе булган Гата ибне Әби Рәбах рәхмәтуллаһи галәйһи Пәйгамбәребезнең истигъфар һәм шөкер итүе белән бәйле бер вакыйга турында сөйли:

Хәзрәти Гайшәгә:

«Аллаһ Рәсүленең син күргән иң гаҗәпләндергән эш-гамәле турында миңа сөйли алмыйсыңмы?» – дидем. Гайшә анабыз:

«Аның нинди хәле гаҗәпләндерми калган микән! – диде һәм сүзен дәвам итте. – Бер төнне яныма килеп ятты, күпмедер вакыттан соң:

*«Рөхсәт итсәң, торып, Раббыма гыйбадәт кылыйм»*, – диде.

Мин исә:

«Валлаһи, Синең белән бергә булырга телим, ләкин Син сөйгән нәрсәне ныграк яратам», – дидем.

Шуннан соң Ул торды, тәһарәтләнде, аннары намазга басты һәм елый башлады. Шулкадәр елады ки, күз яшьләре күкрәген чылатты. Соңыннан рөкугъка китте, аннары сәҗдәгә капланды, сәҗдәдә чакта да елады, аннары сәҗдәдән башын күтәрде һәм тагын елады. Бу хәл нәкъ Билал радыйаллаһу ганһе килеп, иртәнге азанны әйткәнче дәвам итте. Хәбиби Әкрәм әфәндебезнең елавын күргәч, Хәзрәти Билал:

«И, Аллаһның Рәсүле, узган һәм киләчәк бөтен гөнаһларыгыз ярлыканган килеш Сезне бу хәтле нәрсә елатты?» – дип сорады.

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«(Йә Билал!) Аллаһка бик күп шөкер итүче кол була алмыйм микән? Валлаһи, бу төндә миңа шундый аятьләр иңдерелде, аларны укып та, бу хакта фикер йөртмәгәннәргә үкенеч-газап булсын!»* – диде һәм менә бу аяти кәримәләрне укыды:

إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ لَآيَاتٍ لِأُولِي الْأَلْبَابِ. اَلَّذِينَ يَذْكُرُونَ اللَّهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَى جُنُوبِهِمْ وَيَتَفَكَّرُونَ فِي خَلْقِ السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَذا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

**«Һичшиксез, күкләрнең һәм җирнең яралтылуында, төн белән көннең бер-берсен алыштыруында акыл ияләре өчен** (Аллаһның бирдән-берлеген күрсәтә торган) **билгеләр бар. Алар аякта торганда да, утырган килеш тә, янтыкларында килеш тә Аллаһны зикер итәләр һәм күкләр белән җирнең яратылышы турында фикерлиләр: "И, Раббыбыз! Син моны юкка яралтмадың. Син (**һәртөрле кимчелекле сыйфатлардан) **пакьсең! Безне җәһәннәм газабыннан сакла!** (дип ялварырлар)**"»** («Әли Гыймран», 190–191)» (Ибне Хиббан, II, 386).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге сүзләре белән Җәнабел-Хак җибәргән нигъмәтләрнең гыйбадәт-коллыкны киметү түгел, киресенчә, шөкерне арттыру өчен бер сәбәп булырга тиешлеген белдерә.

Югарыдагы аяти кәримәләрдә, аерым алганда, өч нәрсәгә игътибар юнәлтелә. Болар – илаһи бөеклек турында фикерләү, бу олуглык каршында бәндәнең гаҗизлеген төшенү һәм, моның табигый нәтиҗәсе буларак, ахирәттәге хисап көнендә мәрхәмәткә өмет итеп, Рәхим иясенә сыену һәм ялвару.

Әлеге аяти кәримәләр иңдерелгән төндә Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм күктәге йолдызларны көнләштерерлек кадәр күз яшьләре белән таң атканчы елаган. Аллаһның рәхмәте белән мөэминнәрнең дә күз яшьләре, һичшиксез, кара төннәрнең зиннәт-бизәге, караңгы каберләрнең яктысы, ахирәттәге җәннәт бакчаларының чык тамчылары ул.

Тәүбәнең иң кыйммәтле вакыты – сәхәр вакытлары. Җәнабел-Хак илаһи нигъмәтләргә лаек бәхетле колларының сәхәрләрне уяу уздырган тәкъва затлар икәнен аятьләрендә белдерә:

كَانُوا قَلِيلًا مِنَ اللَّيْلِ مَا يَهْجَعُونَ وَبِالْأَسْحَارِ هُمْ يَسْتَغْفِرُونَ

**«Алар төннең бик аз өлешендә йоклыйлар иде. Алар сәхәрләрдә дә ярлыкау сорыйлар иде»** («әз-Зарият», 17–18).

وَالَّذِينَ يَبِيتُونَ لِرَبِّهِمْ سُجَّدًا وَقِيَامًا

**«Алар** (Рахманның коллары ки) **Раббылары өчен сәҗдә кылып һәм аягүрә торып төнне үткәрәләр»** («әл-Фуркан», 64).

Сәхәрләрдән соң шәфәкъ вакыты җитеп, караңгылык ничек эреп таралса, сәхәр вакытларындагы тәүбә-истигъфарларыбыз да, гөнаһ караңгылыгыннан

котылып, нурлы мәгъфирәт яктысы белән күрештергән күркәм гамәл булып тора.

Җәнабел-Хак барчабызга уяу йөрәкләр һәм мәгъфирәт кырларында бәхет-сәгадәт насыйп кылсын!

Амин!..

*Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм*





Хәзрәти

# Идрис

*галәйһиссәләм*

*Күкләрнең хәйран калдырырлык серләрен белгән*

# ХӘЗРӘТИ ИДРИС

*галәйһиссәләм*

Риваятьләрдә Идрис галәйһиссәләмнең Вавилон тирәсендә туганлыгы әйтелә. Хәзрәти Адәмнең алтынчы буын оныгы санала.

Пәйгамбәрлек вазифасы йөкләнгәнче дә, Идрис галәйһиссәләм гомерен гыйбадәттә уздыра. Игелекле затлар белән аралаша, үз кул көче бәрабәренә тапкан ризык белән көн күрә. Кешелек тарихында тегү эше, ягъни тегүчелек һөнәре беренче тапкыр Идрис галәйһиссәләм белән башлана.

Идрис галәйһиссәләм яшәгән җәмгыять Кабил нәселеннән килгән җәмәгать була. Аның әһелләре рухи яктан да, эш-гамәлләре белән бозыклыкка бата. Шит галәйһиссәләм күрсәткән юлдан тайпылып, гыйбадәттән баш тарталар. Төрле хәрәм гамәлләрне һәм әшәкелекләрне хәләл нәрсә, дип уйлыйлар. Хак юлдан читкә киткән бу кавемгә Җәнабел-Хак Идрис галәйһиссәләмне пәйгамбәр итеп җибәрә. Аңа утыз сәхифә иңдерелә. Аллаһның кушканнары һәм тыйганнары белдерелә. Идрис галәйһиссәләм әлеге илаһи әмерләр һәм тыюлар турында җәмәгатькә сөйли, аларны иманга чакыра.

Идрис галәйһиссәләмнең җәмәгать әһелләре рәвешенә кереп, фәрештәләр пәйгамбәрн зиярәт кыла, аның белән очрашып, әңгәмә дә коралар. Идрис галәйһиссәләмнең якынча мең кешедән гыйбарәт мөэмин җәмәгате була.[53] Кавеменә хикмәтле сүзләр белән мөрәҗәгать итеп, ул үгет-нәсыйхәт кыла. Менә аларның кайберләре:

«Акыллының дәрәҗәсе күтәрелгәнчә, тыйнаклыгы да артыр».

«Акыллы зат башка берәүнең гөнаһына карамас! Кешенең гаебен йөзенә бәреп әйтмәс! Мал-мөлкәте күбәйгән саен, тәкәбберләнеп, әдәп-әхлагын бозмас!»

«Нәфес пакьлеген сакламаганның акылы юк дигән сүз!»

«Ахирәт һәм дөньяны ярату бергә була алмас!»

«Дога кылган вакытта, ниятегез эчкерсез, дөрес булсын!»

Идрис галәйһиссәләм гомеренең ахырына таба күккә күтәрелә. Әлеге хәл турында «Мәрьям» сүрәсенең 57 нче аятендә хәбәр ителә:

53. Ибне Кутәйбә, «Мәгариф», 10 б.

وَرَفَعْنَاهُ مَكَانًا عَلِيًّا

**«Без аны өстен бер урынга күтәрдек!»**

Бу өстен урын, дигәндә, Аллаһ Тәгаләгә якын дәрәҗә, җәннәт яисә дүртенче кат күк күз уңында тотыла. Әлеге аятькә кагылышлы бер хәдис-шәриф бар:

*«Мигъраҗда дүртенче кат күккә күтәрелгәч, Мин Идрис (пәйгамбәр) белән очраштым. Җәбраил миңа:*

*“Син күргән зат – Идрис. Аңа сәлам бир!”* – ди.

*Мин Аңа сәлам бирдем. Ул да минем сәламемә җавап бирде. Аннары (миңа):*

*“Мәрхабә, изге кардәш, изге пәйгамбәр!” – диде»* (Бохари, «Бәдьуль-Халк», 6; Мөслим, «Иман», 259–264).

Кайбер галимнәр Идрис галәйһиссәләм хәзер дә күктә кала, хәзер дә яши, дигән фикер яклы.

Идрис галәйһиссәләмнең тугрылыгы, гаделлеге һәм фазыйләте «Мәрьям» сүрәсенең 56 нчы аяти кәримәсендә түбәндәгечә искә алына:

وَاذْكُرْ فِي الْكِتَابِ إِدْرِيسَ إِنَّهُ كَانَ صِدِّيقًا نَبِيًّا

**«Китапта Идрисне дә искә ал. Һичшиксез, ул һәм изге (зат), һәм бер пәйгамбәр иде»**.

«Әнбия» сүрәсенең 85–86 нчы аяти кәримәләрендә исә мондый сүзләр бар:

وَإِسْمَعِيلَ وَإِدْرِيسَ وَذَا الْكِفْلِ كُلٌّ مِنَ الصَّابِرِينَ. وَأَدْخَلْنَاهُمْ فِي رَحْمَتِنَا إِنَّهُمْ مِنَ الصَّالِحِينَ

**«**(И, Хәбибем) **Исмәгыйльне, Идрисне һәм Зүлкифлне дә искә ал! Аларның һәрберсе сабыр итүчеләрдән иде. Без аларны рәхмәтебезгә керттек. Һичшиксез, алар изге кешеләрдән иде».**

Коръәни-Кәримдә пәйгамбәрләр турында сөйләгәндә телгә алынган «салих» сүзе ул пәйгамбәрләрнең фазыйләтен аңлата.

Мәүләна куддисә сирруһ икесе дә күккә күтәрелгән Хәзрәти Идрис белән Гайсә галәйһимәс-сәләм турында болай бәян кыла:

«Идрис һәм Гайсә галәйһимәс-сәләм гайре табигый дәрәҗәдә сабыр, тәкъва була һәм Аллаһ юлында көрәштә фәрештәләргә тиңләшә. Ашау-эчүдән калыр дәрәҗәгә җитәләр. Фәрештәләр белән тиңләшерлек булганга күрә, күккә күтәрелделәр…»

Сабырлыкта, шөкер итүдә һәм аз белән канәгать булуда җаннарының камиллеккә ирешүе нәтиҗәсендә, аларның илаһи рәхмәткә тиенеп, фәрештәләр кебек күккә алынуы гади бәндәләрнең дә нәфес тәрбиясе һәм йөрәкнең пакьлеге аша бик зур дәрәҗәләргә күтәрелә алуына ишарәли.

Рухи камиллекнең иң югары дәрәҗәсенә ия булган пәйгамбәрләр – гомерләренең матди тарафы ягыннан да кешелек өчен үрнәк. Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм җир эшкәртеп, Хәзрәти Идрис галәйһиссәләмнең тегүчелек белән көн күрә. Кешелек тарихы белән бергә башланган изге язу Хәзрәти Идрис галәйһиссәләм чорында үстерелә, баетыла.

Кыскасы, Хәзрәти Идрис галәйһиссәләм:

– Үзенә сәхифә-язу иңдерелгән пәйгамбәр;

– Изгелеге, тугрылыгы һәм фазыйләте белән Коръәни-Кәримдә искә алынган;

– Тегүчелек эшенә нигез салучы;

– Аллаһ тарафыннан югары дәрәҗәгә күтәрелә;

– Сабырлык символы дәрәҗәсенә ирешкәннәрдән;

– Изге пәйгамбәрләрдән;

– Аллаһның рәхмәтенә лаек була.

Галәйһиссәләм!..

# ЙӨРӘК ҺӘМ АНЫҢ СЕРЛӘРЕ

Идрис галәйһиссәләмнең тормышы безгә дәрәҗәле күк серләренә һәм саф йөрәкнең Аллаһ рәхмәтенә ни рәвешле лаек булганын күрсәтә. Шулай ук хайваннардан түбән дәрәҗә белән фәрештәләрдән өстен дәрәҗәләр арасында була алган бәндәнең, камиллеккә ирешеп, фәрештәләргә хас үзенчәлекләр, хөрмәт казана алу мөмкинлегенә ачык үрнәк тәкъдим итә.

Тәннең һәм рухи дөньяның үзәге булып торган йөрәк, пакьләнеп һәм тәрбияләнеп, Аллаһның рәхмәте һәм юмартлыгы белән шундый дәрәҗәгә ирешә ки, ул йөрәкнең хуҗасы, килеш-кыяфәткә башка кешеләрдән аерылып тормавына карамастан, рухи яктан фәрештәләрдән югарырак дәрәҗәләргә лаек була.

Әлеге үзенчәлек Идрис галәйһиссәләмгә хас сыйфат-хасиятләр булганга күрә, бу бүлектә күңел дөньясы, йөрәк турында бераз мәгълүмат бирүне кирәк дип таптык.

Кешенең дөньядагы иң мөһим вазифасы һәм иң җитди шөгыле мәңгелеккә – үлемнән соң тормышка әзерләнүдән гыйбарәт. Бу исә бары тик йөрәкнең хикмәтле вазифасын белү, аны һәртөрле куркынычлардан, начарлыклардан саклап, күркәм әхлакка юнәлдерү аша гына чынга аша ала. Дөньялыктагы иминлек һәм бәхеткә дә, ахирәттәге муллык, хакимлеккә дә сәламәт, изге йөрәккә ия булганда гына ирешергә мөмкин.

«Калеб» сүзе телдә бернәрсәне капма-каршысына әйләндерү, төс һәм рәвешен үзгәртү мәгънәсен дә белдерә. Шундый сыйфатка ия йөрәкләр дә изге һәм фәрештәләргә хас гамәлләр белән нәфескә буйсынып эшләнгән, шайтани гамәлләр арасында гомер буе бәргәләнеп йөри.

Кешедәге һәм җәмгыятьтәге камиллек һәм бозыклык, таркалу һәр очракта да йөрәкләрнең тәрбиясенә, үсешенә яки аларның түбәнчелеккә төшүенә, бозылуына бәйле. Игелек тулы йөрәк күркәм әхлак, изге эшләр һәм матур гамәлләрдә ачыла. Шул рәвешле бәндә «ахсәни тәквим», ягъни иң күркәм дәрәҗәгә ирешә.

Нәфескә буйсынган йөрәкләрне исә көферлек, ширек, начар холык, шәһвәт һәм вәсвәсә биләп ала. Бу очракта йөрәк яратылыш максатына каршы килә һәм сукырая. Андый йөрәк ияләре «бәл һүм әдалл», ягъни хайваннан да түбәнрәк дәрәҗәгә төшә. Моны аяти кәримә дә раслый:

وَلَقَدْ ذَرَأْنَا لِجَهَنَّمَ كَثِيرًا مِنَ الْجِنِّ وَالإِنْسِ لَهُمْ قُلُوبٌ لَا يَفْقَهُونَ بِهَا وَلَهُمْ أَعْيُنٌ لَا يُبْصِرُونَ بِهَا وَلَهُمْ آذَانٌ لَا يَسْمَعُونَ بِهَا أُولَئِكَ كَالْأَنْعَامِ بَلْ هُمْ أَضَلُّ أُولَئِكَ هُمُ الْغَافِلُونَ

**«Без җеннәрдән һәм кешеләрдән күбесен** (үз теләкләре белән лаек булганнарны) **җәһәннәм өчен яралттык. Аларның йөрәкләре бар, алар белән аңламаслар. Аларның күзләре бар, алар белән күрмәсләр. Аларның колаклары бар, алар белән ишетмәсләр. Алар хайваннар кебек. Хәтта алар ныграк адашкан. Алар – гафил кешеләр»** («әл-Әгъраф», 179).

Котыртучы нәфес һәм шайтанның хәйлә-мәкереннән йөрәкне гыйбадәт, зикер, изге әңгәмәләр һәм күркәм әхлак белән генә саклап була. Болар ярдәмендә бәндәдә тәкъвалык уяныр һәм ныгыр, ә Аллаһ катында чын өстенлек үлчәве шуннан гыйбарәт тә. Җәнабел-Хак:

إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِنْدَ اللَّهِ أَتْقَيكُمْ

**«…Шөбһәсез, Аллаһ хозурында иң кадерлегез – бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз!..»** – дип белдерә («әл-Хуҗурат», 13).

Тәкъвалык хәлен саклап тору өчен, изге, тугры затлар белән дуслык, аралашу һәм якын мөнәсәбәт тоту таләп ителә. Йөрәкләрне рухи яктан саклау һәм тәрбияләү максатыннан, мондый мәҗлесләрдә, очрашуларда алга чыккан илаһи бәрәкәтнең әһәмияте бик зур. Андый мәҗлесләр пәйгамбәрлек нурыннан килгән күңел иминлеге, белемнәр ачылган изге урыннар булып тора. Чиксез бәрәкәт, муллык иясе булган Җәнабел-Хактан бәндәләрнең күңеленә кертелгән бу белем һәм нурның тәүге урыны Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең күңел шәрифе дип санала. Шуннан ул изгеләрнең һәм тугрыларның күңелләренә күчә. Изге, тугры бәндәләрдән исә, бер-бер артлы, аларга якынлык һәм мәхәббәт тойганнарның күңелләренә тарала.

Хәзерге заман психология фәне дә раслаганча, кеше мохит тәэсиренә бирелә торган мәхлук булып тора. Кешеләрнең холыклары һәм эш-гамәлләре бер-берсенә йогынты ясый, чөнки җаннар арасындагы рухи алыш-биреш инкяр ителә алмый. Ниндидер энергия рәвешендәге даими бәйләнеш саклана, ягъни актив һәм тәэсир көченә ия шәхесләрдәге рухи омтылышлар алар янәшәсендәгеләргә аларның теләк-ихтыярына нисбәтле дәрәҗәдә күчә ала. Шул рәвешле изге, тугры затлар белән дус булучылар алар кебек изгелек, дөреслек сыйфатын үзләштерер. Шуңа күрә дә аяти кәримәдә, бу күренешнең әһәмиятенә бәйле рәвештә, «тәкъвалык иясе булу» белән «тугры кешеләр бергә булу» бер-бер артлы телгә алына:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَكُونُوا مَعَ الصَّادِقِينَ

**«И, иман китерүчеләр! Аллаһтан куркыгыз (тәкъвалыкта булыгыз) һәм тугры кешеләр белән бергә булыгыз!»** («әт-Тәүбә», 119).

Йөрәкнең пакьлеген саклый алмау кешелек абруена, дәрәҗәсенә каршы бик зур җинаять һәм авыр югалту булып тора.

Калебләрен шайтани теләкләргә корбан итүчеләрне газаплы җәһәннәм көтә. Йөрәк, асылда, хаклык һәм хакыйкать компасы кебек. Бәндә ихтыярының угы кайсы тарафка – яхшылыккамы әллә явызлыккамы юнәлә һәм ул кайсы юнәлештә гамәл кыла, гыйбадәте өчен бәяләмәне дә шуның нигезендә ала. Хәдис-шәрифтә:

*«Шиксез, Аллаһ Тәгалә сезнең кыяфәтләрегезгә һәм малларыгызга түгел, йөрәкләрегезгә һәм гамәлләрегезгә карар!»* – дип әйтелә (Мөслим, «Бирр», 34).

Рухи халәтләренә күрә, йөрәкләр биш төркемгә аерып карала.

**1. Мөһерле һәм бикле йөрәкләр.**

Бернинди дә рухи өстенлеккә, яхшы сыйфатка ия булмаган мондый йөрәкләр, тулысынча хайвани инстинктларга бирелеп, дөньяны бары ашау-эчү һәм кәеф-сафа кору кебек тән-вөҗүднең вакытлы теләкләрен канәгатьләндерүдән гыйбарәт итеп күрә. Кешегә һәм табигатькә салынган илаһи серләрне һәм үзенчәлекләрне ачыклый алырлык аң-зиһеннән алар бик ерак. Пәйгамбәрләрнең һәм Аллаһ дусларының йөрәкләренә нәкъ капма-каршы хәлдәге әлеге калебкә ия гәүдәләр кабердәге мәеттән аерылмый диярлек. Җәсәдләр туфракта ничек череп югалса, мондый калебләр дә илаһи хөкемнәрне инкяр итү нәтиҗәсендәге караңгылык һәм сазлыкта шулай ук юкка чыгарлар. Юлдан язган бу калебләр үзләрен генә түгел, аларга якын йөрүчеләрне дә аяныч язмышка дучар итә. Андыйлар турында Җәнабел-Хак болай ди:

أَفَلَا يَتَدَبَّرُونَ الْقُرْآنَ أَمْ عَلَى قُلُوبٍ أَقْفَالُهَا

**«Алар Коръән турында һич уйламыйлармы? Әллә йөрәкләрендә йозаклар бармы?»** («Мөхәммәд», 24).

Мондый бәндәләр дөньялыкта Аллаһ нигъмәтләре эчендә яшәп, ул нигъмәтләрнең чын хуҗасыннан йөз чөерәләр, Аның әмерләрен һәм тыюларын кире кагу кебек, бик зур рәхмәтсезлек һәм әхлаксызлык үрнәге күрсәтәләр. Җәнабел-Хак андый кешеләр турында аяти кәримәләрдә болай ди:

صُمٌّ بُكْمٌ عُمْيٌ فَهُمْ لَا يَرْجِعُونَ

**«**(Алар) **саңгырау, телсез, сукырлар.** (Шуңа күрә алар хакыйкатькә) **кайта алмаячак»** («әл-Бәкара», 18).

إِنَّكَ لَا تُسْمِعُ الْمَوْتَى وَلَا تُسْمِعُ الصُّمَّ الدُّعَاءَ إِذَا وَلَّوْا مُدْبِرِينَ. وَمَا أَنْتَ بِهَادِي الْعُمْيِ عَنْ ضَلَالَتِهِمْ إِنْ تُسْمِعُ إِلَّا مَنْ يُؤْمِنُ بِآيَاتِنَا فَهُمْ مُسْلِمُونَ

**«Һичшиксез, син үлеләргә дә ишеттерә алмассың, саңгырауларга да чакыруны ишеттерә алмассың, бигрәк тә алар артка борылып качкан вакытларында. Син сукырларны адашуларыннан борып, туры юлга кертә алмаячаксың. Син Безнең аятьләребезгә ышанган кешеләргә ишеттерә алырсың!»** («ән-Нәмел», 80–81).

Җәнабел-Хак андый йөрәкләрнең мөһерле һәм бикле булганын түбәндәгечә хәбәр итә:

خَتَمَ اللَّهُ عَلَى قُلُوبِهِمْ وَعَلَى سَمْعِهِمْ وَعَلَى أَبْصَارِهِمْ غِشَاوَةٌ وَلَهُمْ عَذَابٌ عَظِيمٌ

**«Аллаһ аларның йөрәкләренә һәм колакларына мөһер сукты, күзләрендә исә – пәрдә. Аларга бик зур газап булачак»** («әл-Бәкара», 7).

Аятьтә искә алынган мөһерле һәм бикле йөрәк ияләренең хакыйкатькә һәм игелеккә ишекләре ябылган, кешелекклелек, рухи тормыш белән элемтәләре өзелгән. Калебләрендәге мөһерләрне һәм йозакларны бары алар оныткан Аллаһ кына ача ала.

Бу хәлдә бөтен кешелекне куркуга төшерәчәк илаһи сер һәм хикмәт яшеренгән. Дөньялыкта йөрәге мөһерләнеп, һидәят ишекләре ябылган кешеләрне без белмибез, алар Аллаһка гына мәгълүм, чөнки Җәнабел-Хак һидәятне үзе теләгән колына үлем килгәнче насыйп кыла.

Коръәни-Кәримдә йөрәкләре мөһерләнгән затлар турында искә алынса да, андыйларны берәм-берәм санап чыгу мөмкин түгел, чөнки язмыш безгә билгесез. Фиргавеннең сихерчеләрен мисал итеп телгә алырга була, алар юлдан язып, бозыклыкта яшәп, гомер ахырында һидәяткә ирешә, ә менә Карун һәм Бәлгам ибне Багура кебекләр, киресенчә, һидәят нигъмәтендә яшәп, ахыр чиктә гамәл дәфтәрен газап-хәсрәт белән ябып куя. Димәк, мөэминнәр, мондый аятьләрне ялгыш аңлап, Аллаһның диненә өндәү эшенә бармак аша карамаска тиешләр. Икенче яктан караганда, үзенең шундый куркыныч хәлгә төшәргә мөмкинлегеннән куркып, һәр бәндә Аллаһ Тәгаләдән йөрәгенә һәрдаим иман ныклыгы сорарга һәм гөнаһлардан тыелу өчен уяу тормыш алып барырга бурычлы. Чөнки йөрәкләр, тиешле игътибар күрсәтмәгәндә, һидәяттән ерагая, Аллаһны искә алганда ката башлый, хәтта таштан да катырак нәрсәгә әйләнә ала. Аяти кәримәдә мондый хәл түбәндәгечә сурәтләнә:

ثُمَّ قَسَتْ قُلُوبُكُمْ مِنْ بَعْدِ ذلِكَ فَهِيَ كَالْحِجَارَةِ أَوْ أَشَدُّ قَسْوَةً
وَإِنَّ مِنَ الْحِجَارَةِ لَمَا يَتَفَجَّرُ مِنْهُ الْأَنْهَارُ وَإِنَّ مِنْهَا لَمَا يَشَّقَّقُ فَيَخْرُجُ مِنْهُ الْمَاءُ
وَإِنَّ مِنْهَا لَمَا يَهْبِطُ مِنْ خَشْيَةِ اللّهِ وَمَا اللّٰهُ بِغَافِلٍ عَمَّا تَعْمَلُونَ

**«Шуннан бу булганнан соң, күңелләрегез таш кебек катты яки тагы да катырак булды. Һичшиксез, ташлар арасында да чишмәләр бәреп чыкканы бар; һичшиксез, алар арасында да ярылып, эченнән су чыккannары бар һәм, һичшиксез, Аллаһтан курыкканнары сәбәпле, тәгәрәп төшкәннәре бар. Аллаһ исә сезнең кылганнарыгыздан гафил түгел»** («әл-Бәкара», 74).

Шуңа күрә Аллаһ Тәгалә, йөрәкләрен мөһерләнеп бикләп куелудан сакласыннар өчен, кисәтеп куя:

وَلَا تَكُونُوا كَالَّذِينَ نَسُوا اللّهَ فَأَنْسَاهُمْ أَنفُسَهُمْ أُولَئِكَ هُمُ الْفَاسِقُونَ

**«Аллаһны онытткан, шул сәбәпле Ул да аларга үз-үзләрен оныттырган кешеләр кебек булмагыз. Әнә шулар – фасикълар»** («әл-Хәшер», 19).

**2. Авыру йөрәкләр.**

Болар исән-сау калебләр белән мөһерле калебләр арасында тора. Коръәни-Кәримдә авыру йөрәкләр турында:

فِي قُلُوبِهِمْ مَرَضٌ فَزَادَهُمُ اللّهُ مَرَضًا وَلَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ بِمَا كَانُوا يَكْذِبُونَ

**«Аларның күңелләрендә чир бар. Аллаһ аларның чирләрен көчәйтте. Ялган сөйләүләре сәбәпле, алар өчен тилмерткеч бер газап»**, – дип әйтелә («әл-Бәкара», 10).

Аяти кәримәдә йөрәкләре чирле булуы хәбәр ителгән бу затлар иман китергәнлекләрен бары тел белән генә әйтә, ләкин нәфесләре басымы астында булганга күрә, изге гамәлле тормыш алып бармыйлар. Иман андыйларның йөрәкләренә тулысынча кереп урнашмаган.

Андый йөрәк ияләренең хәле тәннәре авыру кешеләрнең газаплы хәленә охшаган. Аларның дөнья тормышында да гармония юк, күңелләре дә тынычлык, рәхәтлек таба алмый. Күңел дөньясындагы билгесезлек бәндәнең тышкы мохитенә, ә тышкы мохитендәге тәртипсезлек күңел халәтенә тискәре йогынты ясый. Аллаһ Тәгалә мондый кешеләрнең хәлен түбәндәге аятьтә искә ала:

أُولَئِكَ الَّذِينَ اشْتَرَوُا الضَّلَالَةَ بِالْهُدَى فَمَا رَبِحَتْ تِجَارَتُهُمْ وَمَا كَانُوا مُهْتَدِينَ

**«Алар – һидәят урынына адашу юлын сатып алучылар, ләкин аларның бу сәүдәләре файда китермәде, һәм алар туры юлда булмадылар»** («әл-Бәкара», 16).

Аллаһның аятьләрен тиешенчә аңларга комачаулый торган сыйфатлар – тәкәбберлек, үз-үзеңне ярату, көнчелек һәм дөньялыкны сөю кебек йөрәк чирләре. Андый кешеләр, рухи тәрбия алмыйча, калебләрен пакьләмичә торып, Аллаһ разый булырлык күркәм әдәп-әхлакка ирешә алмас һәм Коръән серләрен төшенмәсләр.

سَأَصْرِفُ عَنْ آيَاتِيَ الَّذِينَ يَتَكَبَّرُونَ فِي الْأَرْضِ بِغَيْرِ الْحَقِّ

**«Мин хаксыз рәвештә җирдә тәкәбберләнгәннәрне аятьләремнән борачакмын...»** («әл-Әгъраф», 146) рәвешендәге илаһи кисәтү моны бик ачык белдерә.

Димәк, рухи тәрбия юнәлешендә алга бармаган очракта, йөрәк, Коръән, табигать һәм кешедәге серләрне тиешле дәрәҗәдә аңлап, кабул итәргә сәләтсез. Аяти кәримәдә Җәнабел-Хак:

أَفَلَمْ يَسِيرُوا فِي الْأَرْضِ فَتَكُونَ لَهُمْ قُلُوبٌ يَعْقِلُونَ بِهَا أَوْ آذَانٌ يَسْمَعُونَ
بِهَا فَإِنَّهَا لَا تَعْمَى الْأَبْصَارُ وَلَكِنْ تَعْمَى الْقُلُوبُ الَّتِي فِي الصُّدُورِ

«(И, Хәбибем, Синә каршы килүчеләр) **аңлый ала торган йөрәкләре яки ишетә торган колаклары була торып, җирдә һич гизмәделәрме әллә? Һичшиксез, күзләр сукыр түгел, ләкин күкрәкләр эчендәге йөрәкләр сукыр»**, – дип ачыклый («әл-Хаж», 46). Әлеге аяти кәримә, табигатькә һәм тирә-юньдәге вакыйгаларга күңел күзе һәм гыйбрәтле караш белән карап, илаһи үчкә, илаһи газапка тарыган кавемнәрнең язмышыннан сабак ала белүнең йөрәкләрне савыктырып, аларга шифа бирәчәген аңлата.

Түбәндәге хәдис-шәриф йөрәкне һәртөрле авырудан саклау кирәклеген бик күркәм аңлатып бирә:

**«Белеп торыгыз, дөреслектә, тәндә бер ит кисәге бар, ул сәламәт булса, бөтен тән сәламәт була, ул авырса, бөтен тән авырый. Ул ит кисәге – йөрәк»** (Бохари, «Иман», 39).

Галимнәр калеб чирләрен, гомумән алганда, игътикадый һәм әхлакый авырулар рәвешендә ике төркемгә аерып карый. Мондый классификациягә ярашлы, инкяр, икейөзлелек, ширек, наданлык һәм шөбһәләнү кебек иманнан тайпылулар – «игътикадый авырулар»; шәһвәткә бирелү, гөнаһка йөз тоту, куркаклык, саранлык, рия, тәкәбберлек, көнчелек һәм дөньялыкны ярату кебек сыйфатлар «әхлакый авырулар» дип бәяләнә.

Йөрәктәге чирнең төп сәбәбе, нигезе җаһиллек һәм игътикад зәгыйфьлеге аркасында нәфеснең теләк-омтылышларына буйсыну белән бәйле. Итагатьсезлекнең артуы исә авыруның көчәюенә һәм, ихтимал, йөрәкнең бикләнеп мөһерләнүенә дә китерә.

Тискәре хис-тойгылар, фикерләр һәм мөнәсәбәтләр сәбәпле пәрдә белән капланган йөрәк хакыйкатьне күрмәс хәлгә җитә, күргән очракта да кимчелекле яки ялгыш күрә. Бу исә йөрәкнең хак һәм хакыйкать нәрсәләргә шикләнеп каравына һәм сукыраюына юл ача. Иманның төп урыны булган калеб шул рәвешле җәрәхәтләнсә, иман да, көч-куәтен югалтып, изге гамәлләр кыла алмас дәрәҗәгә төшәр. Мондый йөрәк Аллаһ һәм Аның Рәсүленә карата тиешле мәхәббәтне тоеп, хөрмәт күрсәтә алмаган кебек, үзен гыйбадәткә багышларга да сәләтле булмас.

Йомгаклап әйткәндә, йөрәкләр авыру һәм гафил булганда, гамәлләр Хак Тәгалә катында кыйммәтен югалтыр. Аллаһ Тәгалә нуры белән яктыртылмыйча торып, калебләр сукырая барыр һәм хис-тойгы сәләтеннән мәхрүм калыр. Андый калебләр табигатьтәге илаһи серләр салынган мең дә бер бизәкне, искиткеч матурлыкны күрә алмас хәлгә төшәр.

**3. Гафил йөрәкләр.**

Йөрәккә кагыла торган иң төп рухи авыруларның берсе – ваемсызлык (гафләт). Ул, калебне чолгап алып, кешене рухи эш-гамәлләрдән, омтылышлардан аерып куя. Аяти кәримәдә мондый кисәтү ясала:

وَلَا تُطِعْ مَنْ أَغْفَلْنَا قَلْبَهُ عَنْ ذِكْرِنَا وَاتَّبَعَ هَوَاهُ وَكَانَ أَمْرُهُ فُرُطًا

**«...**(Гыйсьян сәбәпле) **Без аның күңелен Безне зикер итүдән гафил кылдык һәм ул бозык теләкләренә ияргән, эше дә чамадан узган. Андый кешеләргә итагать итмә!»** («әл-Кәһф», 28).

Башка бер аяти кәримәдә исә:

وَاذْكُرْ رَبَّكَ فِي نَفْسِكَ تَضَرُّعًا وَخِيفَةً وَدُونَ الْجَهْرِ مِنَ الْقَوْلِ
بِالْغُدُوِّ وَالْآصَالِ وَلَا تَكُنْ مِنَ الْغَافِلِينَ

**«Иртәләрен һәм кичләрен түбәнчелек һәм курку белән, кычкырмыйча һәм үз эчеңнән Раббыңны зикер ит һәм гафилләрдән булма!»** – дип («әл-Әгъраф», 205), йөрәкнең зикердән туктавы ваемсызлыкка илтәчәге белдерелә. Ваемсызлык көчәйгән саен, йөрәк тә катылана барыр. Җәнабел-Хак андый затларның газаплы хәле турында хәбәр бирә:

فَوَيْلٌ لِلْقَاسِيَةِ قُلُوبُهُمْ مِنْ ذِكْرِ اللَّهِ أُولَئِكَ فِي ضَلَالٍ مُبِينٍ

**«…Аллаһның зикеренә** (карата йөрәкләре) **каты булганнарга ни үкенеч! Алар ап-ачык бер адашу эчендә»** («әз-Зүмәр», 22).

Икенче аяти кәримәдә зикердән тыелган кешенең шайтан капкынына эләгәчәге, азгынлыкка биреләчәге һәм, нәтиҗәдә, кешелек сыйфатларын югалтып, шайтанның бер уенчыгына әйләнүен аңлата:

وَإِخْوَانُهُمْ يَمُدُّونَهُمْ فِي الْغَيِّ ثُمَّ لَا يُقْصِرُونَ

**«**(Шайтаннарның) **кардәшләре исә бозыклыкта ярдәмче булырлар, аннары туктатмаслар»** («әл-Әгъраф», 202).

Гафил йөрәк белән кылынган гамәлләр Хак Тәгалә катында кабул ителмәс һәм бушка киткән булыр.

Мондый авырулар йоктырган калебләр һичшиксез дәвага мохтаҗ һәм рухи тәрбия алырга тиеш. Аларны дәвалау өчен кайбер мәсьәләләргә игътибар бирү зарур. Бу мәсьәләләрнең кайберләрен карап китик:

**а) Хәләл ризык.**

Гыйбадәтләребезне тәнебезнең көч-хәле бәрабәренә кыла алабыз. Хәләл ризык бәндә вөҗүденә бәрәкәт һәм изгелек бирсә, хәрәм һәм шикле ризыклар сагыш-көенеч китерә. Күренекле суфилар күңел дөньясының үсеше өчен мөһим ике нәрсәгә игътибар юнәлтә:

«Ашаганда, авызыгызга кергән нәрсәгә, сөйләшкәндә, авызыгыздан чыккан нәрсәгә игътибар итегез, бу мәсьәләдә бик таләпчән, катгый булыгыз!»

Абдулкадыйр Гәйлани куддисә сирруһ та ризыкның йөрәкне пакьләүдәге әһәмиятенә басым ясый:

«Кара, балам! Хәрәм ризык йөрәкне үтерер. Шундый ризык бар, ул йөрәгеңне нурландырыр; шундый ризык бар, аны караңгылыкка батырыр. Шундый ризык бар, ул сине дөнья белән мәшгуль итәр, шундый ризык бар, ахирәт, мәңгелек турында уйландырыр. Шундый ризык бар, сине ике дөньяның да заһиденә[54] әйләндерер, күңелне дөнья һәм ахирәтне Бар кылучыга юнәлтер. Хәрәм ризык сине дөнья мәшәкатьләренә батырыр һәм гөнаһ эшләрне сиңа бизәп, матурлап күрсәтер. Мөбах ризык сине ахирәт турында уй-фикерләргә этәрер, сиңа гыйбадәтне яраттырыр. Хәләл ризык исә йөрәкне Мәүлага (Аллаһка) якынайтыр. Ашамлыкларның сыйфаты һәм йогынтысы бары Аллаһны тану белән генә билгеләнә, бәяләнә ала. Аллаһны танып белү исә йөрәк белән эшләнә, китап-дәфтәрдә түгел. Хак Тәгаләне танып белү мәхлуктан түгел, ә Аллаһтан йөрәккә иңдерелә. Бу исә Аллаһның берлеге һәм барлыгын раслап, илаһи хөкемнәр белән гамәл кылганнан соң гына чынга аша».

54. Заһид – хәтта шикле нәрсәләрдән дә тыелып, гөнаһтан качучы, Аллаһтан куркучы зат.

Хәләл нигъмәтләр кулланганда да, баланс саклау мөһим, исраф кылырга ярамый. Аяти кәримәдә:

وَآتِ ذَا الْقُرْبَى حَقَّهُ وَالْمِسْكِينَ وَابْنَ السَّبِيلِ وَلَا تُبَذِّرْ تَبْذِيرًا.
إِنَّ الْمُبَذِّرِينَ كَانُوا إِخْوَانَ الشَّيَاطِينِ وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِرَبِّهِ كَفُورًا

**«Якынга хакын бир. Юксылга һәм юлда калганга да. Һәм, белештермичә, исраф итмә. Исраф итүче кешеләр – шайтаннарның кардәшләре. Шайтан исә – Раббысына карата инкярчы»**, – дип әйтелә («әл-Исра», 26–27). Бер хәдис-шәрифтә исә:

اِنَّ مِنَ السَّرَفِ أَنْ تَأْكُلَ كُلَّ مَا اشْتَهَيْتَ

*«Җаның теләгән һәрнәрсәне ашау, шөбһәсез, исраф була!»* – дип кисәтү ясала (Ибне Мәҗә, «Әтгыймә», 51).

Ризыкның хәләл булу шарты үтәлгән очракта, кунак сыйлаганда юмартлык күрсәтү киңәш ителә һәм моның исраф булмаячагы турында искә алына.

**б) Коръәни-Кәримне аңлап-фикерләп уку.**

Коръәни-Кәримне аңлап-фикерләп уку, ягъни әмер һәм тыюларның хикмәте турында уйлау, кыйссалардан гыйбрәт алу тиеш. Йөрәкләребез никадәр пакьләнгән булса, Коръәни-Кәримнең бәрәкәте безгә шулкадәр ныграк тәэсир итәр. Коръәни-Кәримнең калебтәге рухи чирләргә шифа булуы турында аяти кәримәдә хәбәр ителә:

وَنُنَزِّلُ مِنَ الْقُرْآنِ مَا هُوَ شِفَاءٌ وَرَحْمَةٌ لِلْمُؤْمِنِينَ وَلَا يَزِيدُ الظَّالِمِينَ إِلَّا خَسَارًا

**«Без мөэминнәр өчен шифа һәм рәхмәт булган Коръәнне иңдерәбез. Әмма ул залимнәргә зарардан башка берни дә арттырмый»** («әл-Исра», 82).

Әбү Зәрр радыйаллаһу ганһе риваять кыла:

«Йә, Рәсүлүллаһ! Миңа үгет-нәсыйхәт бир», – дидем.

*«Сиңа тәкъва булырга киңәш бирәм, чөнки тәкъвалык – һәр эшнең башы ул»*, – дип әйтте.

«Йә, Рәсүлүллаһ! Миңа тагын бераз нәсыйхәт укы», – дип кабат мөрәҗәгать иттем. Пәйгамбәребез:

*«Коръән укуга һәм Аллаһны зикер итүгә игътибар бир, чөнки Коръән җирдә синең өчен бер нур, күктә бер ризык булып тора»*, – дип җавап бирде (Ибне Хиббан, «Сахих», II, 78).

Башка хәдис-шәрифтә Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләре китерелә:

*«Коръәнне укып, аның белән яшәгән затка (ахирәттә):*

*“Укы һәм күтәрел, дөньялыкта ничек тырышып укыган булсаң, шулай укы! Чөнки синең урының үзең укыган иң соңгы аятьнең югарылыгында”*, – *дип әйтелә»* (Әбү Давыт, «Витр», 20).

**в) Гыйбадәтләрне хошуг белән үтәү.**

Йөрәк чирләрдән арына алсын өчен, гыйбадәтләрне хошуг белән кылырга тырышу таләп ителә, чөнки Җәнабел-Хак гыйбадәтләрнең хошугсыз үтәлүен теләми һәм болай ди:

فَوَيْلٌ لِلْمُصَلِّينَ. الَّذِينَ هُمْ عَنْ صَلَاتِهِمْ سَاهُونَ

**«Намаз укыганнарга ни үкенеч! Намазларында гафилләргә»** («әл-Мәгун», 4–5).

Мөфәссир Әлмалылы Хәмди Языр бу аятьне түбәндәгечә тәфсир кыла:

«Алар намазның әһәмиятенә игътибар бирмичә, аны җиренә җиткереп, җитди вазифа буларак башкармыйлар;

– Намаз уку-укымауга бармак аша карыйлар;

– Аның вакытына игътибар итмәсләр, вакытының узу-узмавына ваемсыз карап, гыйбадәтне кичектерәләр;

– Намазны калдыруга борчылмаслар;

– Намазны кылган очракта да, Аллаһ ризалыгы өчен ихлас ният белән укымыйча, бер төркем дөньяви максатларда укыйлар;

– Кешеләр белән бергә булганда намаз укысалар, ялгыз калган вакытта укымыйлар; кылсалар да, Хак Тәгалә хозурында кебек хошуг һәм хөрмәт белән түгел, кыланып кына кылалар» («Хак Дини Куръан Дили», IX, 6168).

«Мөэминүн» сүрәсендә:

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ. الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ

**«Иман китерүчеләр хәзердән уңышка иреште. Кемнәр намазларында түбәнчелеклеләр** (хошуглы)**»**, – диелә («әл-Мүэминүн», 1–2).

Башка аяти кәримәдә исә намазны хошуг белән укуның ничек чынга ашырыла алганы аңлатыла:

وَاسْتَعِينُوا بِالصَّبْرِ وَالصَّلوةِ وَإِنَّهَا لَكَبِيرَةٌ إِلَّا عَلَى الْخَاشِعِينَ.
الَّذِينَ يَظُنُّونَ أَنَّهُمْ مُلَاقُوا رَبِّهِمْ وَأَنَّهُمْ إِلَيْهِ رَاجِعُونَ

**«Сабырлык һәм намаз белән ярдәм сорагыз. Һичшиксез, ул – бик олуг эш, түбәнчелекле** (хошуглык иясе) **булмаган кешеләрдән кала. Ул кешеләр Раббыларын очратуга һәм Аңа кайтачакларына шиксез ышаналар»** («әл-Бәкара», 45–46).

Хошугны кайберәүләр курку, кыенсыну кебек йөрәк гамәлләреннән берсе буларак аңлата; кайберәүләр исә аны кирәксез хәрәкәтләрдән тыелу һәм тынлыкта гыйбадәт кылу кебек әгъзаларга караган гамәлләргә бәйләп карый. Чынлыкта, хошуг асылы – йөрәктә, тышкы чагылышы бәдәндә булып, аларның икесен дә колачлый. Йөрәккә караган ягы Раббының бөеклеге һәм кодрәтлеге каршында үзеңнең зәгыйфьлегеңне күреп, нәфесне Хак Тәгалә кушканнарга буйсындырудан, бик югары әдәп, хөрмәт хисе тоюдан гыйбарәт. Тышкы күренеш белән бәйле тарафы исә тән әгъзаларын әнә шул хис-тойгылар тәэсирендә тынычлык, сүзсезлек биләп алуны, намазда күзләрнең тирә-якка түгел, алга һәм сәҗдә урынына гына каравын белдерә.

Әгәр игътибар итсәгез, аяти кәримәдә, намазны хошуг белән уку өчен, бәндәнең гүя «Аллаһ белән кавышкан» һәм «Аңа әйләнеп кайткан» кебек рухи халәткә керүе кирәклеге гаять ачык белдерелә. Ягъни намазның бәдән белән йөрәкнең үзара гармониясендә кылынуы зарури. Әнә шундый намаз гына мөэминне фәхеш һәм бозыклыклардан саклый ала.

Баһаветдин Нәкышбәнди куддисә сирруһтан: «Бәндә намазда ничек итеп хошугка ирешер?» – дип сорагач, ул болай дип җавап бирә:

«Дүрт нәрсә белән:

1. Хәләл ризык;

2. Тәһарәт алганда ваемсызлыктан тыелу;

3. Тәүге тәкбирне әйткәндә, үзеңне Аллаһ хозурында дип күзаллау;

4. Намаздан тыш та Җәнабел-Хакны һич онытмау».

Бу сүзне аяти кәримә дә раслый:

اَلَّذِينَ هُمْ عَلَى صَلَاتِهِمْ دَائِمُونَ

**«Алар – намазларын дәвам итүчеләр»** («әл-Мәгариҗ», 23).

Гыйбадәтләрдә хошуглыкка ирешү һәм гыйбадәтләрдән тыш та үзеңне гүя намазда кебек хис итә алу өчен, сау-сәламәт йөрәккә ия булып, буш, артык

сүз һәм гамәлләрдән мөмкин кадәр ераграк йөрү, алардан тыелу кирәк. Аяти кәримәдә:

وَالَّذِينَ هُمْ عَنِ اللَّغْوِ مُعْرِضُونَ

**«**(Алар) **буш нәрсәләрдән йөз чөерүчеләр»**, – дип әйтелә («әл-Мүэминүн», 3).

Әлеге сүзләр башка гыйбадәтләргә дә кагыла. Бу мәсьәләгә карата Җәнабел-Хак болай ди:

وَالَّذِينَ يُؤْتُونَ مَا آتَوْا وَقُلُوبُهُمْ وَجِلَةٌ أَنَّهُمْ إِلَى رَبِّهِمْ رَاجِعُونَ

**«Алар** (мөэминнәр) **биргән нәрсәләрен** (хәер-сәдакаларын) **үзләре Раббыларына кайтарылачаклар дип, күңелләре белән куркып бирәләр.** (Башка тәфсиргә күрә: кылган һәр эшләрен өркү-курку хисе белән башкаралар)**»** («әл-Мүэминүн», 60).

أَلَمْ يَعْلَمُوا أَنَّ اللّٰهَ هُوَ يَقْبَلُ التَّوْبَةَ عَنْ عِبَادِهِ وَيَأْخُذُ الصَّدَقَاتِ

**«...Алар Аллаһ колларыннан** (эчкерсез) **тәүбәне кабул иткәнен һәм** (ихлас күңелдән биргән) **сәдакаларын алганын белмиләрме әллә?..»** («әт-Тәүбә», 104).

Аятьтә сәдаканы, ягъни инфакны да (Аллаһ юлында сарыф итү), намаз кебек үк риясызлык һәм хошуг белән бирергә кушыла. Мондый шарт хәдис-шәрифтәге «уң кулың биргәнне, сул кулың белмәсен» сүзләре белән дә дәлилләнә (Бохари, «Азан», 36).

**г) Аллаһны зикер итүдә дәвамлылык.**

Коръәни-Кәримдә «зикер» сүзе 250 тапкырдан артык очрый. Зикер – колның Раббысын еш искә алуы һәм Аны һичвакыт онытмавы дигән сүз. Аяти кәримәләрдә Аллаһ Тәгаләне иртән дә, кичен дә, басып торганда да, утырганда да, яткан хәлдә дә, кыскасы, һәрдаим һәм бик күп зикер итәргә кушыла. Мондый аятьләрнең берничәсен мисал итеп китерик:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اذْكُرُوا اللّٰهَ ذِكْرًا كَثِيرًا. وَسَبِّحُوهُ بُكْرَةً وَأَصِيلًا

**«И, иман китерүчеләр! Аллаһны күп итеп зикер кылыгыз. Көн башында һәм көн ахырында Аңа тәсбих итегез»** («әл-Әхзәб», 41–42).

اَلَّذِينَ يَذْكُرُونَ اللّٰهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَى جُنُوبِهِمْ

**«Алар** (чын акыл иясе мөэминнәр) **аякта торганда да, утырган килеш тә, янтыкларында килеш тә Аллаһны зикер итәләр...»** («Әли Гыймран», 191).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм «Һичкем булмаган аулак урыннарда Аллаһны зикер итеп, яшерен генә елаган» кешеләрнең кыямәт көнне бернинди дә күләгә калмаган вакытта, Җәнабел-Хак гареше күләгәсендә ышыкланып торачагы турында шатлыклы хәбәр тапшыра.[55]

Йөрәк пакьләнеп, рухи дәрәҗәгә ия була алсын өчен, Аллаһны дәвамлы рәвештә зикер кылу бик зур әһәмияткә ия. Мөэминнәр зикернең мөһимлеген кыямәт көнне тагын да яхшырак аңлаячак. Җәннәткә керүче мөэминнәр турында Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

لَمْ يَتَحَسَّرْ أَهْلُ الْجَنَّةِ اِلَّا عَلَى سَاعَةٍ مَرَّتْ بِهِمْ لَمْ يَذْكُرُوا اللهَ تَعَالَى فِيهَا

*«Җәннәт халкы башка нәрсә өчен түгел, бары тик дөньяда Аллаһны зикер итмичә уздырган вакытлары өчен хәсрәт һәм үкенеч тоячак!»* – дип әйтә (Һәйсәми, X, 73–74).

**д) Төннәрне уяу уздыру.**

Төннәрне – дөньяның иңенә-буена күрә сайлап тегелгән иминлек һәм нигъмәт киеме дип атарга мөмкин. Физик һәм рухи яктан яшеренергә теләгәннәр өчен камил япма ролен үти алар. Төннең бу сыйфаты турында «Нәбә» сүрәсендә:

وَجَعَلْنَا اللَّيْلَ لِبَاسًا

**«Төнне Без бер пәрдә иттек»**, – дип бик анык хәбәр ителә («ән-Нәбә», 10). Чыннан да төннең саулык, җәмгыять, әхлак һәм матурлык өчен кирәкле вазифаларны башкарган бер кием булуы бәхәссез. Кеше, үз эчке дөньясына игътибар юнәлтеп, көн дәвамында җыелган физик һәм рухи авырлыкларны читкә алып ташлый алсын өчен, төннең тынлыкка төренүе шарт, чөнки якты көннәргә төннең бәдәни һәм рухи ял бирү сыйфаты хас түгел. Төн нигъмәтен аңламаганнар көннәрнең яхшы якларын төшенә алмый. Төннең төрле начар эшләргә һәм буш нәрсәләргә сарыф ителүе иртәнең сәламәтлеген һәм бәрәкәтен юкка чыгару дигән сүз.

Бәндә өчен төннең тынлыкка чумган мизгелләреннән дә бәрәкәтлерәк вакытлар була алмый. Төннәрне билгеле бер күләмдә уяу уздырып, аның игелеге һәм бәрәкәтеннән файдалану тиеш. Бу уңайдан аяти кәримәләрдә болай диелә:

تَتَجَافَى جُنُوبُهُمْ عَنِ الْمَضَاجِعِ يَدْعُونَ رَبَّهُمْ خَوْفًا وَطَمَعًا وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنْفِقُونَ.
فَلَا تَعْلَمُ نَفْسٌ مَا أُخْفِيَ لَهُمْ مِنْ قُرَّةِ أَعْيُنٍ جَزَاءً بِمَا كَانُوا يَعْمَلُونَ

55. Карагыз: Бохари, «Азан», 36; Мөслим, «Зәкят», 91.

«(Намаз һәм истигъфар кылу өчен, төннәрен ул тәкъва затларның) **янтылары ятаклардан аерыла. Курку белән һәм өмет белән Раббыларына ялваралар, аларны Без ризыкландырган нәрсәләрдән сарыф итәләр. Кылган эшләре өчен, күзләргә куаныч булачак нәрсәләрнең алар өчен яшерелгәнен һичкем белми»** («әс-Сәҗдә», 16–17).

وَمِنَ اللَّيْلِ فَاسْجُدْ لَهُ وَسَبِّحْهُ لَيْلًا طَوِيلًا

**«Төнлә дә Аңа сәҗдә кыл.Төннең озын бер өлешендә Аны тәсбих ит!»** («әл-Инсан», 26).

Төннең илаһи һәм рухи күренешләренә шаһит булу өчен, аннан максатлы рәвештә, игелекле ният белән файдалану тиеш.

كَانُوا قَلِيلًا مِنَ اللَّيْلِ مَا يَهْجَعُونَ. وَبِالْأَسْحَارِ هُمْ يَسْتَغْفِرُونَ

**«Алар** (чыннан да тәкъвалык ияләре) **төннең бик аз өлешендә йоклыйлар иде. Алар сәхәрләрдә дә ярлыкау сорыйлар иде»** («әз-Зарият», 17–18).

وَمِنَ اللَّيْلِ فَتَهَجَّدْ بِهِ نَافِلَةً لَكَ عَسَى أَنْ يَبْعَثَكَ رَبُّكَ مَقَامًا مَحْمُودًا

**«Төннең бер өлешен исә синең өчен генә өстәлгән буларак, уяу килеш уздыр. Раббыңның сине мактаулы урынга** (шәфәгать урынына) **урнаштыруы катгый билгеләнде»** («әл-Исра», 79).

Тәһәҗҗүд намазы шушы аяти кәримә белән Пәйгамбәребезгә фарыз, безгә исә, Аның өммәтенә, сөннәт-мөәккәдә кылына. Җәнабел-Хак андый мөһим сөннәтне дәвамлы кылучыларны мактап телгә ала:

وَالَّذِينَ يَبِيتُونَ لِرَبِّهِمْ سُجَّدًا وَقِيَامًا

**«Алар** (Рахманның коллары)**, Раббылары өчен сәҗдә кылып һәм аягүрә торып, төнне үткәрәләр»** («әл-Фуркан», 64).

Башка аяти кәримәдә Җәнабел-Хак болай ди:

الَّذِي يَرَاكَ حِينَ تَقُومُ. وَتَقَلُّبَكَ فِي السَّاجِدِينَ

«(И, Рәсүлем!) **Ул Зат синең торганыңны да күрә. Сәҗдә кылучылар арасында үзгәргәнеңне дә»** («әш-Шугара», 218–219).

Әлеге аяти кәримәнең тәфсирендә Бәйдави мондый аңлатма бирә:

«Өммәт өчен биш вакыт намаз фарыз кылынып, төнге намаз сөннәт дәрәҗәсенә күтәрелгәч, сәхабәләренең хәл-әхвәлен белешү нияте белән, Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм, төнлә, үзе яшәгән сәгадәт йортыннан

чыгып, сәхабәләрнең өйләре тирәсендә йөри һәм бу өйләрнең Коръән моңнары, зикер һәм тәсбих авазлары белән умарта кебек гөжләп торганына шаһит була» («Әнварут-Тәнзил», IV, 111).

**е) Изге һәм тугры кешеләр белән бергә булу.**

Йөрәкне саклау, аның сәламәтлеген һәм алгарышын тәэмин итү өчен, изге һәм тугры кешеләр белән бергә булу таләп ителә. Калеб янәшәдәгеләрнең рухи йогынтысына бирелә, шул рәвешле шәхси сыйфатлар үзгәрә башлый. Рухи яктан көчле шәхесләр, зәгыйфьрәкләргә тәэсир итеп, алар өчен үзенә күрә илһам чыганагына әверелә. Ягъни изге һәм тугры затларның шәфкате, мәрхәмәте, рухи нәзакәтлеге һәм башка күркәм сыйфатлары тирә-юньдәгеләргә күчә. Әсхабе Кирамның өммәттәге иң фазыйләтле затлар булуына сәбәп тә аларның Аллаһ Рәсүле белән якыннан аралашып, Аның белеменнән, бәрәкәтеннән үзләренә насыйп өлеш алуда яшеренгән. Җәнабел-Хак аяти кәримәдә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَكُونُوا مَعَ الصَّادِقِينَ

**«И, иман китерүчеләр! Аллаһтан куркыгыз һәм тугры кешеләр белән бергә булыгыз!»** – дип боера («әт-Тәүбә», 119).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә тугры холыклы кешеләр белән бергә булуның әһәмиятен мондый мисал белән гаять үтемле аңлата:

*«Яхшы дус белән начар дуска мисал итеп, мускус ташучы кеше белән күрек өрдерүче кешене атарга мөмкин. Мускус хуҗасы сиңа хушбуй тәкъдим итәр яки син аннан сатып аласың. Күрек белән өрдереп ут яндыручы исә синең тәнеңне яки киемеңне яндыра яисә аннан сиңа начар ис сеңеп, күчеп кала»* (Бохари, «Буйүгъ», 38).

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм исән чакта гына түгел, үлгәч тә изге бәндәләр белән якын булуның әһәмиятенә хәдис-шәрифендә басым ясый:

*«Вафат булган якыннарыгызны изге кешеләр арасына җирләгез»* (Дәйләми, «Муснәд», I, 102).

Изге кешеләр белән якын мөнәсәбәттә торучылар, вакыт узу белән, үз холык-табигатенә бәйле рәвештә, изгелекләрен арттырыр. Бозыклар янында йөрүчеләр исә үзләре дә бозылыр. Рухи мохит, тискәре булсынмы ул, уңаймы, һәрдаим йөрәккә йогынты ясый, чөнки һәр органның билгеле бер ирадәгә, теләккә буйсынуына карамастан, йөрәктә генә һичнинди чит ирадә юк һәм калеб тирә-юнь тәэсирләренең үзенә сеңдергән юнәлешенә борылучан, омтылышына ияручән, буйсынучан.

Локман галәйһиссәләмнең улына биргән киңәшләре дә, калебнең мондый үзенчәлегенә ишарәләп, изге, галим кешеләр бергә булу әһәмиятенә игътибар юнәлтә:

«Балам! Галим затлар белән бергә бул һәм алар белән аралашуны туктатмаска тырыш! Чөнки Аллаһ Тәгалә, яңгыр белән туфракка җан керткән кебек, хикмәт нуры белән йөрәкләрне дә җанландыра» (Әхмәд ибне Ханбәл, «Зүһд», № 551).

Сәхабә ханымнар Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күреп калырга соңарган, моңа әллә ни омтылмаган һәм Аның белән озак вакыт күрешмичә йөргән балаларын ачулана торган булган. Мәсәлән, берничә көн Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәртәбәле хозурына күренмәгән һәм Аның белән сөйләшмәгән өчен, Хузәйфә радыйаллаһу ганһене әнисе әрләгән. Хузәйфә әлеге гыйбрәтле хәлне болай искә ала:

«Әнием миннән:

“Пәйгамбәребез белән соңгы тапкыр кайчан очраштың?” – дип сорады. Мин:

“Инде берничә көн Аның белән күрешмәдем”, – дидем. Миңа бик каты кызды һәм ачуланып кыйнады. Мин исә:

“Тукта әле, кызма! Хәзер үк Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барам, Аның белән бергә ахшам намазын укыйм, аннары минем һәм синең өчен тәүбә-истигъфар сорап, дога кылуын сорыйм”, – дидем» (Тирмизи, «Мәнакыйб», 30; Әхмәд ибне Ханбәл, «Муснәд», V, 391–2).

**4. Зикер итүче йөрәкләр.**

Бу дәрәҗәдәге калеб зикер белән нурланган була, илаһи нур нәфесне үз хакимлегенә ала, иман, калеб җәүһәре белән берләшеп, ныклы, ышанычлы иман дәрәҗәсенә ирешә.

Хак Тәгалә зикерне иң олуг гыйбадәт дип бәяли һәм аяти кәримәләрдә иман китерүчеләргә һәрдаим зикердә булырга куша:

وَلَذِكْرُ اللّٰهِ أَكْبَرُ

**«…Аллаһны зикер итү исә өстенрәк** (иң зур гыйбадәт)**…»** («әл-Ганкәбут», 45).

وَاذْكُرِ اسْمَ رَبِّكَ وَتَبَتَّلْ إِلَيْهِ تَبْتِيلًا

**«Раббыңның исемен зикер ит һәм тулысынча өзеп, Аңа гына багышла!»** («әл-Мүззәммил», 8).

فَاذْكُرُونِي أَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوا لِي وَلَا تَكْفُرُونِ

**«Мине искә алыгыз, Мин дә сезне искә алырмын. Миңа шөкер итегез, Миңа карата шөкерсез булмагыз!»** («әл-Бәкара», 152).

Бөек Раббыбыз зикернең хикмәтен аңлаган һәм аны барлык фани ләззәтләрдән өстен күргән колларын мактый, аларның дөнья зиннәтләренә алданмавын һәм йөрәкләренең зикер аша хозурлыкка ирешүен белдерә:

رِجَالٌ لَا تُلْهِيهِمْ تِجَارَةٌ وَلَا بَيْعٌ عَنْ ذِكْرِ اللَّهِ

**«Шундый** (изге) **ирләр** (бар)**, сәүдә дә, сату да аларны Аллаһны зикер итүдән, намаз укудан һәм зәкят бирүдән читкә юнәлдерми!..»** («ән-Нур, 37).

أَلَا بِذِكْرِ الله تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ

**«…Күңелләр Аллаһны зикер итү белән генә тынычланмыймы?!»** («әр-Рәгъд», 28).

وَالذَّاكِرِينَ اللَّهَ كَثِيرًا وَالذَّاكِرَاتِ

**«…Аллаһны күп итеп зикер иткән ирләр һәм зикер иткән хатыннар...»** («әл-Әхзәб», 35) аяти кәримәсе белән Җәнабел-Хак дәвамлы зикердә булган ир-атлар һәм хатын-кызларны аерым-аерым телгә ала.

Аллаһны зикер кылуда дәвамлылык йөрәктә Аллаһ Тәгаләгә карата мәхәббәт үсентеләрен яшәртеп җибәрә һәм аны, фани дөньяның кызыктыргыч ләззәтләреннән ерагайтып, илаһи мәхәббәт белән тутыра. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Аллаһны сөю билгесе – Аллаһ Тәгаләне зикер итүне сөю ул», –* дип әйтә (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 52).

Бу күзлектән караганда, зикердән тыелган затларга, Аллаһ мәхәббәтеннән мәхрүм калганга күрә, илаһи куркыныч яный.[56] Аяти кәримәдә зикердән баш тартуның куркынычы хакында болай диелә:

وَمَنْ يَعْشُ عَنْ ذِكْرِ الرَّحْمنِ نُقَيِّضْ لَهُ شَيْطَانًا فَهُوَ لَهُ قَرِينٌ. وَإِنَّهُمْ لَيَصُدُّونَهُمْ عَنِ السَّبِيلِ
وَيَحْسَبُونَ أَنَّهُمْ مُهْتَدُونَ. حَتَّى إِذَا جَاءَنَا قَالَ يَا لَيْتَ بَيْنِي وَبَيْنَكَ بُعْدَ الْمَشْرِقَيْنِ فَبِئْسَ الْقَرِينُ

**«Кем дә кем Рахманның зикереннән сукыр калырга тырышса, Без аның янына бер шайтан куячакбыз, һәм ул аңа бик якын. Һичшиксез, алар** (шайтаннар) **аларны юлдан боралар. Алар исә аларны** (шайтаннарны) **һидәят тапкан кешеләр дип саныйлар. Ул Безгә** (хисап тотарга) **килгәннән**

56. Карагыз: «әз-Зүмәр» сүрәсе, 22.

**соң: “Аһ, минем белән синең арада көнчыгыш белән көнбатыш ераклыгы булса иде. Син нинди начар иптәшсең!” – дип әйтер** («әз-Зүхруф», 36–38).

Кеше үзен туры юлдан тайпылдырачак һәм иманнан яздырачак шайтаннан Аллаһны зикер итү юлы белән сакланырга һәм күркәм әхлак иясе булырга тырышырга тиеш. Күркәм әхлакка һәм яхшы холык сыйфатларына исә бары тик Җәнабел-Хактан курку, Аны бик нык ярату һәм Аны еш-еш зикер итү аша гына ирешеп була.

Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе, зикер мәҗлесләрен мактап, зикернең кирәклегенә игътибар бирә:

«Зикер һәм Аллаһның нигъмәтләрен хәтерләтү өчен җыелган мәҗлесләрдән дә фазыйләтлерәк ни була ала? Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм әсхабе кирамны бер түгәрәккә җыя да бергәләп Аллаһны зикер кылалар иде».

Зикер рухи тәэсир генә ясап калмый, аның физик йогынтысы да бар:

فَكُلُوا مِمَّا ذُكِرَ اسْمُ اللّٰهِ عَلَيْهِ إِنْ كُنْتُمْ بِآيَاتِهِ مُؤْمِنِينَ

**«Өстендә Аллаһның исеме телгә алынганнардан ашагыз. Әгәр сез Аның аятьләренә ышанган кешеләр булсагыз!»** – аяти кәримәсе («әл-Әнгам», 118) әнә шул хикмәткә ишарәли.

Зикернең төрле төрләре бар. Аллаһны болай итеп, тегеләй итеп искә алыгыз, дигән аерым бер әмер юк. Һәр зикернең үз фазыйләте, үз кыйммәте телгә алына. Кыйммәте, дәрәҗәсе һәм нәтиҗәсе ягыннан караганда, зикерләрнең иң күркәме – «Исме әгъзам» зикере, гомумән алганда, сүз «лафзатуллаһ» турында бара. «Аллаһ» исеме бөтен исемнәрнең мәгънәләрен үзенә җыйган. Шуңа күрә Аллаһ исемен башка исемнәрдән аерып торган сыйфаты бар. Мәсәлән, сүз башындагы «ا» (әлиф) алып ташланса, «لل» (лиллаһ) килеп чыга. Беренче «ل» (ләм) хәрефе сызылса, «له» (ләһү) кала. Икенче «ل» (ләм) хәрефе бетерелсә, «ه» (һү) калачак. Боларның һәрберсе Аллаһ Тәгаләгә ишарәли.

Бер хәдис-шәрифтә хәтта табигатьнең яшәеше дә һәрдаим Аллаһны зикер кылуга бәйле икәнлеге белдерелә:

*«Җирдә “Аллаһ, Аллаһ”, диюче берәү булганда, кыямәт купмас»* (Мөслим, «Иман», 234).

«Аллаһ» исеме белән зикер әйтүгә ихлас, сайлап алынган бәндәләргә бик зур әһәмият бирә. Бу зикерне һәрдаим кылып торган Аллаһ коллары булганда, кыямәт купмаячак. Ул бәндәләр шундый сыйфатка ия булыр ки, Аллаһ Җәллә Җәләлүһү дини тормышны шулар белән саклар. Алар кайсы өлкәдә, кайсы җирлектә булсалар, шул тирә иминлек хөкем сөрер.

Кәлимәи-тәүхид (لا اله الا الله) зикерен кабатлау да хәдис-шәрифләрдә гел хуплана. Мәсәлән, шундый хәдисләрнең берсендә Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«(لا اله الا الله) зикерне күп кабатлап, иманыгызны яңартыгыз!»* – дип боера (Хаким, «Мүстәдрәк», IV, 285/7657).

Үзенә бар дөнья белән идарә итү мөмкинлеге бирелгән Сөләйман галәйһиссәләм:

«Минем солтанатым – вакытлы нәрсә. Тәүхид зикере алып киләчәк солтанат исә мәңгелек...» – дип әйткән.

Зикерләр арасында бигрәк тә кәлимәи-тәүхидне бергә җыелып зикер кылуның аерым бер кыйммәте бар. Сәхабәләрдән Шәддад ибне Әвес радыйаллаһу ганһе риваять кылган түбәндәге хәдистә әнә шул үзенчәлек күрсәтелә:

«Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Аның янында булган чакта, безгә мөрәҗәгать итеп:

*“Арагызда чит кешеләр бармы?”* – дип сорады. Монда “чит кеше”, дигәндә, яһүди белән нәсараларны күз уңында тотты.

Без:

“Юк, йә, Рәсүлүллаһ!” – дидек.

Шуннан соң Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, ишекләрне бикләтеп:

*“Кулларыгызны күтәреп, «Лә иләһә илләллаһ», дип әйтегез!”* – дип боерды».

Шәддад ибне Әвес радыйаллаһу ганһе әлеге зикер мәҗлесенең ничек дәвам итүе турында сөйләп бирә:

«Кулларыбызны күпмедер вакытка күтәреп, кушылганча (“Лә иләһә илләллаһ” дип) зикер әйттек. Бездән соң Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә кулларын төшерде һәм дога кылды:

*«Аллаһым, Сиңа мактаулар булсын! Раббым мине “бу җөмлә” белән җибәрдең. Миңа аны (сөйләүне һәм үтәүне) куштың. Шуның бәрабәренә миңа җәннәт вәгъдә иттең. Син беркайчан да вәгъдәдән кире кайтмассың!»*

Аннары Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә болай дип дәште:

*«Сезгә шатлыклы хәбәр булсын! Чынлыкта, Аллаһ Тәгалә сезне гафу итте»* (Әхмәд ибне Ханбәл, «Муснәд», IV, 124).

Башка бер хәдис-шәрифтә бу зикернең фазыйләтләре хакында әйтелә:

*«”Лә иләһә илләллаһ” – Аллаһ катындагы урыны һәм кыйммәте бик зур сүзләр. Кем дә кем аны ихласлык һәм эчкерсезлек белән әйтсә, Аллаһ аны җәннәткә кертер. Кем дә кем аны бары тик теле белән генә әйтсә, җаны һәм малы сакланыр, ләкин иртәгә Аллаһ белән күрешүгә, Аллаһ аны хисапка тартыр»* (Хәйсәми, «Мәҗмәгуз-Зәваид», I, 26).

Һәрвакыт Аллаһны зикер итү һәм үзеңнең сынау мәйданында икәнеңне онытмау зарурлыгын белдергән түбәндәге хәдис-шәриф тә игътибарга лаек.

*«Аллаһны онытып, кирәксез әңгәмәләргә чуммагыз, чөнки Аллаһны искә алмыйча күп сөйләшүләр йөрәкне катыра. Аллаһтан иң ерак торган затның йөрәге каты булыр»* (Тирмизи, «Зүһд», 62).

Кәлимәи-тәүхидне кабатлау үлем мизгелендә дә бик мөһим.

Хәдис-шәрифтә:

*«Кемнең (тормышта чакта әйткән) иң соңгы сүзе «لا اله الا الله» булса, шул җәннәткә керер»*, – дип хәбәр ителә (Әбу Давыт, «Җәнаиз», 15–16/3116).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм йөрәкне тәрбияләү мәсьәләсендә сәхабәләрнең сәләте, мөмкинлегенә карап, зикер өйрәткән. Өмме Хани белән Пәйгамбәребез арасындагы сөйләшү әнә шундый зикер өйрәтүнең яхшы үрнәге булып тора:

Әбү Талибның кызы Өмме Хани радыйаллаһу ганһә Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә:

«Йә, Рәсүлүллаһ! Мин картайдым һәм зәгыйфьләндем. Мин утырган килеш кенә үти алган берәр гыйбадәт киңәш итсәң иде?» – дип үтенеч белән мөрәҗәгать итә.

Шуннан соң Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди:

*«Йөз тапкыр “сөбханаллаһ”, йөз тапкыр “әлхәмдүлиллаһ” һәм йөз тапкыр “Лә иләһә илләллаһ” дип әйт!»* (Ибне Мәҗә, «Әдәб», 56; Әхмәд ибне Ханбәл, «Муснәд», VI, 344).

Кыскасы, Аллаһны зикер итү ул – дөнья мәшәкатьләре караңгылыгыннан котылып, Хак Тәгалә белән күрешү өчен бердәнбер чарасы булган илаһи мәхәббәт ярдәмендә бәндәнең күңелен нурландыруы дигән сүз. Бу дөнья тормышында Раббыбызны никадәр зикер кыла алсак, иртәгә ахирәттә Аның белән күрешү мөмкинлегенә шулкадәр күбрәк насыйп ителәчәк. Шуңа күрә динебездәге зикер һәм тәсбихнең олуглыгын, дәрәҗәсен игътибарсыз калдырырга ярамый. Шулай ук зикернең бәрәкәте йөрәкләрдә урын алганга күрә, әүлия бәндәләр «Һәр төнне – Кадер кичәсе, һәр күргәнне Хозыр Ильяс дип тану» кагыйдәсенә әһәмият биргән, чөнки зикер белән тулган калебләр һәркайсы аерым-аерым сыйфат белән Хак Тәгаләгә ачылган мәхәббәт һәм

кавышу тәрәзәләре булып тора. Кыскасы, Аллаһ Тәгаләгә илтә торган юллар мәхлуклар саны кадәр бихисап күп.

**5. Тере (сәламәт) йөрәкләр.**

Бу – пәйгамбәрләрнең һәм әүлияларның йөрәкләре. Андый затларда Аллаһ Тәгаләнең бер төркем сыйфатлары урын алыр. Тере, сәламәт йөрәклеләр – Аллаһ Җәллә Җәләлүһү, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм Коръәни-Кәрим әхлагы белән камиллеккә ирешкән затлар ул.

Һиҗри исәп белән сигезенче гасырда яшәгән олуг вәлиләрдән Нәҗметдин Күбра хәзрәтләре шәкертләре белән бергә бер изге бәндәнең җеназасында катнаша. Мәет җирләнеп, имам кабер янында тәлкыйн укыган чакта, Нәҗметдин Күбра елмаеп куя. Шәкертләре, мөгаллимнең шундый вакытта елмаюына аптырап, моның хикмәте, сәбәбе белән кызыксыналар. Хәзрәт аңлатырга теләми, ләкин бик үҗәтләнеп сорагач, әйтеп бирә:

«Тәлкыйнне тере кеше үлегә укый. Ләкин монда тәлкыйн кылучы затның йөрәге гафил, ә кабергә кергән мәетнең йөрәге теп-тере. Гафил берәүнең асылда йөрәге тере булган башкага тәлкыйн укуына гаҗәпләндем».

Бөек Аллаһны зикер итеп торган йөрәк Аның тарафыннан яклана һәм саклана. Шулвакытта калеб илаһи серләр дөньясына таба баскыч-баскыч күтәрелә башлый. Аның өчен әйберләрнең хикмәте, кеше һәм табигатьнең серләре ачыла. Бәндә пакь, сәламәт йөрәккә хас сыйфатларына лаек була.

Хак Тәгалә Коръәни-Кәримдә әйтә:

وَمَا أَمْوَالُكُمْ وَلَا أَوْلَادُكُم بِالَّتِي تُقَرِّبُكُمْ عِندَنَا زُلْفَى إِلَّا مَنْ آمَنَ وَعَمِلَ صَالِحًا
فَأُولَئِكَ لَهُمْ جَزَاءُ الضِّعْفِ بِمَا عَمِلُوا وَهُمْ فِي الْغُرُفَاتِ آمِنُونَ

**«Иман итеп, изге гамәл кылган кешеләрдән тыш, ни малларыгыз, ни балаларыгыз сезне Безнең өчен якынайту белән якынайта торган нәрсәләр түгел. Әнә шулар – аларга кылган нәрсәләре сәбәпле, әҗер икеләтә биреләчәк. Алар –** (җәннәттәге) **сарайлар эчендә имин кешеләр»** («Сәбә», 37).

Башка аяти кәримәдә дә йөрәк пакьлеге телгә алына:

يَوْمَ لَا يَنفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ. إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ

**«Бер малның да, улларның да файда бирмәгән көнне. Мәгәр керсез күңел белән** (пакь йөрәк белән) **Аллаһка килүче булмаса гына»** («әш-Шугара», 88–89).

Димәк, бары тик пакьләнгән, сәламәтлеккә ирешкән йөрәк белән генә Хак Тәгаләгә якынаеп була. Бу хакыйкать барлык гыйбадәтләр өчен дә бик мөһим. Мәсәлән, аяти кәримәдә корбан чалуга мөнәсәбәтле рәвештә болай дип әйтелә:

لَنْ يَنَالَ اللّٰهَ لُحُومُهَا وَلَا دِمَاؤُهَا وَلَكِنْ يَنَالُهُ التَّقْوَى مِنْكُمْ

**«Аларның** (корбаннарыгызның) **итләре дә, каннары да Аллаһка ирешәчәк түгел. Аңа сездән бары тәкъвалыгыгыз гына ирешә!..»** («әл-Хаҗ», 37).

Илаһи хәзинәләр һәм серләр кешегә бүләк итеп бирелгән. Җәнабел-Хак үзенең бөеклеген кешенең изге яратылышында танытырга тели. Шул сәбәпле бәндә, үзенең шәрәфлелеген, абруен һәм хөрмәтләнгән зат икәнен төшенгән вакытта гына, чын мәгънәсендә кешегә әйләнер.

Иманлы булып үлүнең, илаһи сөенечләргә тиенүнең юлы – сау-сәламәт йөрәк белән һәрвакыт Аллаһны танып яшәүдән гыйбарәт.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү барыбызга да, үлем килгәнче, шундый йөрәк иясе булырга һәм аның белән һәрдаим Раббыбызны зикер итәргә насыйп кылсын!

Амин!..

***Хәзрәти Идрис галәйһиссәләм***





Хәзрәти

# Нух

*галәйһиссәләм*

## *Туфаны белән көферлектән Җир арынган*

# ХӘЗРӘТИ НУХ

## *галәйһиссәләм*

Нух галәйһиссәләм Коръәни-Кәримдә һәм Пәйгамбәребезнең хәдис-шәрифләрендә мөһим урын алып тора. Улүл-газм пәйгамбәрләрнең берсе санала.[57] Коръәндә исеме төрле сәбәпләргә бәйле рәвештә 43 тапкыр очрый. 28 аятьтән торган 71 нче сүрә аның исеме белән аталган. Атаклы туфан вакыйгасы аркасында кешелекнең «Икенче атасы» дип йөртелә.

Идрис галәйһиссәләм күккә алынганнан соң, кешеләр, хак юлны югалтып, потларга һәм һәйкәлләргә табына башлый. Шуннан соң Нух галәйһиссәләм үз кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрелә.

Хәзрәти Нухның чын исеме «Яшькүр», «Сакин» яки «Габделгаффар» булганлыгы әйтелә. Кушаматы «Нәҗиййуллах» (Аллаһ коткарган) һәм «Шәйхүл-әнбия» (нәбиләрнең озын гомерлесе) була. Шулай ук «Сәййидүл-әнбия» дип йөртелгән пәйгамбәрләр арасында да исеме телгә алына.[58]

Идрис галәйһиссәләм күккә алынганнан соң, аңа иярүчеләрдән Вәдд, Сүва, Йәгус, Йәук һәм Нәср, дин белән яшәп, иманга өндиләр һәм кешеләр арасында югары дәрәҗәгә ирешәләр. Әлеге изге бәндәләр үлгәч, аларны һәрдаим искә алып тору өчен, шайтаннар котырту сәбәпле, һәйкәлләр ясала. Халык акрынлап потпәрәстлеккә йөз тота. Бу һәйкәлләрдә илаһи кодрәт булганлыгына ышана башлыйлар.

Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмә бәян кыла:

*«Нух галәйһиссәләм кавемендә булган потлар соңыннан гарәпләргә күчә. Вәдд исемле пот Думәтул-Җәндәлдә була һәм Кәлеб кабиләсенә карый. Сүва дигән потка Хүзәйлләр табына. Йәгус исемле пот Мурад кабиләсенеке була. Соңрак Бәну Гутайфныкына әйләнә. Сәбәгә якын Җурф дип аталган җирдә куела. Йәук Хәмәданныкы була. Нәср исә Химйәрдәге Али Зил-Кәланыкы санала. Бу потларның исемнәре, асылда, Нух кавемендәге изге затлардан килә. Әлеге изге бәндәләр үлгәч, шайтан аларның кавемнәрен болай дип үгетли:*

*"Изге кешеләрегез яшәгән җирләргә (аларның истәлегенә) һәйкәлләр куегыз һәм бу һәйкәлләргә шуларның исемнәрен бирегез". Халык, бу киңәшне тотып, кушылганны эшли. Баштагы мәлдә сыннарга табынмыйлар. Ләкин*

57. Улүл-газм пәйгамбәрләр – иң югары дәрәҗәле пәйгамбәрләр. Аларга Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Ибраһим, Муса, Гайсә һәм Нух галәйһимәс-сәләм керә.

58. Карагыз: Хаким, «Мүстәдрәк», II, 596/4007.

*ул изге затлар бакыйлыкка күчкәч, алар хакында белем-мәгълүмат та онытыла һәм нәтиҗәдә надан халык шул сын-потларга табына башлый»* (Бохари, «Тәфсир», 71/1).

Куфә ягында, потпәрәстлеккә бирелмичә, тәүхид иманны саклаган бер генә кавем кала. Нух галәйһиссәләм шул кавемнән була.

Нух галәйһиссәләм кайчак көтү көтә, вакыт-вакыт сәүдә белән дә шөгыльләнә. Кавемне Кабил нәселеннән Дәрмәсил исемле бер залим бәндә җитәкли. Һәр кабиләнең аерым поты була. Һәр потка аерым хезмәткәр тотыла. Хәзрәти Нух галәйһиссәләм бу хәлне көлке дип таба. Ул чорда әхлаксызлык һәм потпәрәстлек киң тарала.

**Нух галәйһиссәләм кавеменең үзенчәлекләре**

1. Потпәрәст булалар.

Аларның бу үзенчәлеге аяти кәримәдә түбәндәгечә искә алына:

وَقَالُوا لَا تَذَرُنَّ آلِهَتَكُمْ وَلَا تَذَرُنَّ وَدًّا وَلَا سُوَاعًا وَلَا يَغُوثَ وَيَعُوقَ وَنَسْرًا

**«Алар әйттеләр: “Илаһларыгызны ташламагыз, Вәддне, Сүвагны, Ягусны, Ягукны, Нәсрне кире какмагыз!” – диделәр!»** («Нух», 23).

Потлар һәм аларга табынучылар кешелек тарихында һәрвакыт адәм балаларын, туры юлдан тайпылдырып, адаштырырга тырыша. Хөрмәт һәм хәтер өчен ясалган һәйкәлләр, вакытлар узу белән, табыну объекты булган потларга әйләнә.

Кеше ышанган һәм гыйбадәт кылган илаһны матди бернәрсә, төркем итеп күзаллау антропоморфизм дип атала. Мондый гакыйдә кешеләрне анык формалы нәрсәләргә табынуына һәм ахыр чиктә потчылыкка китерә. Тәүхид диннәренә исә «мөтәгали», ягъни бөтен галәмнәрдән һәм күзаллаулардан бөек бер Аллаһка инану хас. Бу ышану, кеше зиһенен матдилектән ерагайтып, җисми булмаган мәгънәләргә, бөек нәрсәләргә юнәлтә. Бәндә матди дөньяның башка тарафындагы рухи хакыйкатьләрне аңларга тырышыр. Ләкин бәндә зиһене мондый дәрәҗәгә ирешәсе урынга, җиңел юл эзләп, әүвәл Аллаһны җисемләндерү һәм нәрсәгәдер охшату, ягъни Аны үзе яшәгән дөнья үлчәмнәре кысасында күзалларга маташу хатасына бата. Бу исә кешелекнең хак юлдан язып, потчылыкка йөз тотуына сәбәп була.

Ислам дине исә кешедәге мондый теләк-омтылышны иң күркәм рәвештә юкка чыгарып, зиһенгә Аллаһ Тәгаләне ниндидер бер җисемгә охшатуны тыя. Бәндәләр матди булмаган нәрсәләрне җисми хәлгә әйләндереп, шуларга табыну хатасына эләкмәсен өчен дә, ислам сурәт һәм сыннарны хупламый. Рәсем һәм һәйкәлләрнең тагын бер зыяны хыял көчен чикләп, кешенең бөек нәрсәләрне күз алдына китерү һәм аңлау сәләтен юкка чыгарудан гыйбарәт.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм, каберләрне зиярәт кылгандагы артык гамәлләр кешеләрне потпәрәстлеккә илткән өчен, әүвәлрәк мондый зиярәтләрне тыя. Әмма тәүхид иманы шактый ныгыганнан соң, хәдис-шәрифләрендә бу гамәлгә рөхсәт бирә:

*«Сезгә каберләрне зиярәт кылуны тыйган идем. Хәзер инде каберстаннарга бара аласыз!»* (Мөслим, «Җәнаиз», 106).

*«…Каберләрне зиярәт итәргә теләүче моны эшләсен, чөнки каберләрне зиярәт кылу безгә ахирәтне искә төшерә»* (Тирмизи, «Җәнаиз», 60).

Шулвакытта үлем турында һәрчак искә төшерелеп торсын, мәрхүмгә бүләк җибәрелсен, ягъни Коръәни-Кәрим укылсын һәм ахирәт турында даими уйлап йөрелсен өчен, каберләрне зиярәт кылу киңәш ителә. Чынлыкта, күренекле, олуг шәхесләр каберләре янында укылган догалар, әйтелгән теләкләр дә алар хөрмәтенә Җәнабел-Хактан сорау булырга тиеш, чөнки бәндәдән сорау кешеләрне ширеккә илтә. Нух галәйһиссәләм кавемендә дә әнә шул хәл килеп чыга.

Яралтылган бер мәхлукка, бернәрсәгә дә охшамаганга, ягъни «мөхаләфәтүл-лил-һавадис» сыйфатына ия булганга күрә, Аллаһ Җәллә Җәләлүһүгә үлчәм һәм форма кебек бәндә күз алдына китерә ала торган төшенчәләр, бәяләмәләр хас түгел. Шәех Шибли хәзрәтләре болай ди:

«Аллаһ Тәгаләне зиһенегездә, уй-фикерләрегездә төшенеп, акыл белән тулысынча күзалладым дип санийсыз икән, бу уй-фикерләр үзегезгә генә карый, чөнки аларны сез уйлап чыгарырга (моңарчы булмаган) һәм сезнең кебек соңыннан да булдырылырга (уйлап чыгарылырга) мөмкин...»

Бу очракта Шибли хәзрәтләре соңыннан булдырылган нәрсә белән Кадимне (мәңгелек булучы) аера белергә кирәклеген, кешеләр өчен Җәнабел-Хакны тануның бердәнбер юлы Ул үзе белдергән сыйфат һәм үзенчәлекләрне белүдән гыйбарәт икәнлеген һәм башка юл юклыгын аңлатырга тели. Димәк, вәхидә хәбәр ителгәннәрне читкә этәреп, Аллаһны анык бер рәвештә күзалларга, тасвирларга тырышу, әлбәттә, кешене бик авыр һәм ямьсез нәтиҗәләргә китерер.

Җәнабел-Хакның кеше аңы һәм күзаллаулары чигеннән бик күпкә ераклыгын белдерү өчен, галимнәребез менә монда бик кыска аңлатманы истә калдырырга өнди:

كُلُّ مَا خَطَرَ بِبَالِكَ وَاللّٰهُ وَرَاءَ ذٰلِكَ

«Акылыңа Аллаһ Тәгалә белән бәйле нинди генә уй-фикер килсә дә, белеп торыгыз: Бөек Аллаһ андый түгел».

Акыл – соңыннан яралтылган нәрсә. Җәнабел-Хакны шул яралтылган нәрсә белән төшенү мөмкин түгел. Ләкин Муса галәйһиссәләм Җәнабел-Хак белән сөйләшкәч, күңелендә бик зур шатлык тоя. Шундый сөенеч дәртендә ул Җәнабел-Хакны күрергә тели һәм шул хакта үтенечен белдерә. Бу вакыйга аяти кәримәдә искә алына:

قَالَ رَبِّ أَرِنِي أَنْظُرْ إِلَيْكَ قَالَ لَنْ تَرَانِي وَلَكِنِ انْظُرْ إِلَى الْجَبَلِ فَإِنِ اسْتَقَرَّ مَكَانَهُ فَسَوْفَ تَرَانِي

**«…Муса: “И, Раббым! Күрсәт миңа да, карыйм сиңа!” – диде. Ул: “Син Мине күрә алмассың, ләкин шул тауга кара. Әгәр ул урынында тора алса, син дә Мине күрә алырсың”, – диде»** («әл-Әгъраф», 143).

Җәнабел-Хакны күрү бәхете, дәрәҗәләренә бәйле рәвештә, бары җәннәт әһелләренең бер өлешенә генә рөхсәт ителәчәк.

2. Нух галәйһиссәләмнең кавеменә искиткеч залим һәм азгын затлар җыела. Аяти кәримәдә аларның бу золымы һәм бозыклыклары бик анык әйтелә:

إِنَّهُمْ كَانُوا هُمْ أَظْلَمَ وَأَطْغَى

**«…Алар иң залим һәм иң бозык кешеләр иде»** («ән-Нәҗем», 52).

3. Алар фасикъ (юлдан язган) була. Аллаһ Тәгалә:

إِنَّهُمْ كَانُوا قَوْمًا فَاسِقِينَ

**«…Һичшиксез, алар фасикълар (гөнаһлылар, юлдан язганнар) кавеме булдылар»**, – дип белдерә («әз-Зарият», 46).

4. Бу кавем төрле әшәкелекләргә чума. Аяти кәримәдә аларның бу сыйфаты түбәндәгечә белдерелә:

إِنَّهُمْ كَانُوا قَوْمَ سَوْءٍ

**«…Һичшиксез, алар начар кавем иде…»** («әл-Әнбия», 77).

5. Алар намуссыз була. Мәрхәмәт һәм шәфкать хисләреннән мәхрүм Нух кавеменең бу сыйфаты аяти кәримәдә:

إِنَّهُمْ كَانُوا قَوْمًا عَمِينَ

**«…Алар (күңел күзләре, намуслары) сукыр бер кавем иде»**, – дип сурәтләнә («әл-Әгъраф», 64).

6. Алар бик кире, үзсүзле була. Нух галәйһиссәләм кавеме холык-табигатьләре көферлеккә, гөнаһка иялэнгән, дөньяда шушы кирелекне бер принцип итеп алган затлардан тора. Алар ахирәттә дә үзсүзләнеп, үзләренә бер пәйгамбәр килгәнен кире кагачаклар.

Аллаһ Рәсүле саллэллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә:

*«Нух һәм аның өммәте кыямәт көнендә килгәч, Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Нухтан: "Иманга чакырдыңмы?" – дип сорар. Нух галәйһиссәләм: "Әйе, йә Раббы, чакырдым", – дип җавап бирер. Аннары Аллаһ Тәгалә Нухның өммәтенә мөрәҗәгать итеп: "Нух сезне иманга чакырдымы?" – дип сорагач, алар: "Юк, безгә бер пәйгамбәр дә килмәде", – дип җавап бирер. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә Нухка: "Синең хаклыгыңны шаһитлык кылып, кем раслар?" – дигәч, Нух галәйһиссәләм: "Хәзрәти Мөхәммәд һәм Аның өммәте шаһит булыр", – дип әйтер. Алар чынлап та Нухның тәблигъ кылганын шаһитлык итәр».*

Хәдис-шәрифне риваять кылган зат болай дип өстәп куя:

*«Чыннан да, аяти кәримәдә Мөхәммәд галәйһис-саләтү вәс-сәләәм һәм Аның өммәтенең башка пәйгамбәрләр белән аларның өммәтләренә шаһитлык кылачагы ап-ачык белдерелә:*

وَكَذلِكَ جَعَلْنَاكُمْ أُمَّةً وَسَطًا لِتَكُونُوا شُهَدَاءَ عَلَى النَّاسِ وَيَكُونَ الرَّسُولُ عَلَيْكُمْ شَهِيدًا

*"Сез кешеләргә шаһит булырсыз, дип, Рәсүл (Хәзрәти Мөхәммәд) исә сезләргә шаһит булсын, дип, сезне урта өммәт итеп кылдык…"»* («әл-Бәкара», 143) (Бохари, «Тәфсир», 2/13, «Әнбия», 3; Тирмизи, «Тәфсир», 2/2965).

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү хак юлдан тайпылган бу кавемгә Хәзрәти Нух галәйһиссәләмне җибәрә. Аяти кәримәдә бу хакта:

إِنَّا أَرْسَلْنَا نُوحًا إِلَى قَوْمِهِ أَنْ أَنذِرْ قَوْمَكَ مِنْ قَبْلِ أَنْ يَأْتِيَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ

**«Һичшиксез, Без: "Тилмерткеч газап аларга килгәнче, кавемеңне кисәт!" – дип, Нухны кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрдек»**, – дип әйтелә («Нух», 1).

### Озын-озак тәблигъ еллары

Нух галәйһиссәләмгә илле яшь чагында аның янына Җәбраил галәйһиссәләм килә һәм пәйгамбәрлек вазифасы турында хәбәр итә дә: «Дәрмәсил янына һәм аның кавеменә бар, аларны тәүхид иманга чакыр!» – ди. Хәзрәти Нух гомеренең ахырына кадәр бер Аллаһка иман китерергә өндәячәге турында сүз бирә. Коръәни-Кәримдә бу хакта болай диелә:

وَإِذْ أَخَذْنَا مِنَ النَّبِيِّينَ مِيثَاقَهُمْ وَمِنْكَ وَمِنْ نُوحٍ وَإِبْرَهِيمَ
وَمُوسَى وَعِيسَى ابْنِ مَرْيَمَ وَأَخَذْنَا مِنْهُم مِيثَاقًا غَلِيظًا

**«Менә Без бөтен пәйгамбәрләрдән, синнән, Нухтан, Ибраһимнан, Мусадан һәм Мәрьям улы Гайсәдән** (дингә өндәү вазифасын башкару турында) **сүз алган идек. Без алардан катгый сүз алган идек!»** («әл-Әхзәб», 7).

وَلَقَدْ أَرْسَلْنَا نُوحًا إِلَى قَوْمِهِ إِنِّي لَكُمْ نَذِيرٌ مُبِينٌ.
أَنْ لَا تَعْبُدُوا إِلَّا اللهَ إِنِّي أَخَافُ عَلَيْكُمْ عَذَابَ يَوْمٍ أَلِيمٍ

**«Без Нухны кавеменә җибәрдек.** (Нух аларга)**: “Һичшиксез, мин – сезгә аңлатучы бер кисәтүчемен. Аллаһтан башка берәүгә дә гыйбадәт кылмагыз, мин сезнең өчен читен бер көннең газабыннан куркамын”, – диде»** («Һуд», 25–26).

Нух галәйһиссәләм үзенә йөкләнгән вазифаны баштарак яшерен рәвештә башкара, аннары тәблигъ эшен ачыктан-ачык алып бара. Яшь чагында һәркемнең мәхәббәтен яулаган бер зат булуга карамастан, дингә өнди башлагач, вазгыять үзгәрә. Аңа бик аз кеше генә иярә.

Кавемнең башлыгы булган Дәрмәсил Хәзрәти Нухның мондый үгет-нәсыйхәт эшчәнлеге турында белеп алгач, үз янындагылардан: «Кем соң ул?» – дип сорый. Тегеләре исә: «Безнең кавемнән булса да, безгә буйсынмаган бер бәндә... Исеме Нух ибне Ламәк. Әүвәл акыллы иде. Аннары тилерде, үзенең пәйгамбәр булуы турында сөйли!» – диләр. Аннары: «Потларга да каршы килә!» – дигәч, Дәрмәсил Хәзрәти Нухны үз янына чакыра да: «Бәла синең башыңа! Син безнең илаһларыбызны кире кагасыңмы?» – дип ачулана.

Хәзрәти Нух тирәсендә ярлы-ябагай гына йөргәнгә, аны мыскыллаучылар да табыла. Кяферләр Нух галәйһиссәләмгә:

قَالُوا أَنُؤْمِنُ لَكَ وَاتَّبَعَكَ الْأَرْذَلُونَ

**«Әйттеләр: “Иң түбән кешеләр сиңа ияргән икән, без дә сиңа иман китерикме әллә?”»** – дип белдерә («әш-Шугара», 111).

Әлеге надан һәм залим кавем кешеләре тәкәбберлекләре аркасында фәкыйрьләргә һәм ятимнәргә кимсетеп карый. Әмма Нух галәйһиссәләм диненең хаклыгын гына түгел, үзе өндәгән дингә иярүчеләрне дә яклый. Кяферләрнең гаепләүләренә каршы ул мондый җавап бирә:

وَمَا أَنَا بِطَارِدِ الْمُؤْمِنِينَ

**«Мин мөэминнәрне кумаячакмын»** («әш-Шугара», 114).

إِنَّهُمْ مُلاَقُوا رَبِّهِمْ وَلَكِنِّي أَرَاكُمْ قَوْمًا تَجْهَلُونَ.
وَيَا قَوْمِ مَنْ يَنْصُرُنِي مِنَ اللّٰهِ إِنْ طَرَدْتُهُمْ أَفَلاَ تَذَكَّرُونَ

**«…Чөнки, һичшиксез, алар Раббылары белән очрашачаклар. Ләкин мин сезне җаһил кешеләр дип күрәм. И, кавемем! Әгәр мин аларны куа калсам, кем миңа Аллаһтан ярдәм итә алыр? Сез һич кенә дә уйламыйсызмы?»** («Һуд», 29–30).

Дәрмәсил үлгәч, аның урынына улы Нәвлин утыра. Ул тагын да явызрак бәндә була. Нух галәйһиссәләм Нәвлин чорында да тәблигъ эшен дәвам итә. Кавеме аны мыскыллый, өстенә ком-туфрак сибә, кыйнаучылар да табыла. Бервакыт хәтта аңын югалтканчы буалар, аны үлгән, дип уйлыйлар. Һушына килгәч, Нух: «И, Аллаһым! Мине һәм кавемне кичер, чөнки алар нишләгәннәрен белмиләр», – ди. Госел-тәһарәт ала да, кабат шул явызлар янына бара. Аларны Аллаһка иман китерергә һәм гыйбадәт кылырга чакыра.[59] Бөтен шундый җәбер-җәзаларга карамастан, ул бик зур сабырлык күрсәтә. Илаһи рәхмәт чагылышы буларак, аның яраларын кайчак Җәбраил галәйһиссәләм дәвалый.

Мөшрикләр: «Бәла булсын сиңа, әй, Нух! Шушы кыйнауларыбызга карамастан, син һаман дәгъваттан баш тартмыйсыңмыни?!» – диләр. Хәзрәти Нух исә: «Мин тилергән зат түгел. Ата-бабаларыбыз хәзер газап чигә! Акылга килегез!» – дип аларга үгет-нәсыйхәт бирә. Нух галәйһиссәләм сүзен: «Дәгъватымнан йөз чөереп, миңа бер зыян да китерә алмыйсыз!» – дип дәвам итә.

Чөнки кеше ике нәрсәдән курка:

1. Башкаларның зарар китерүеннән;
2. Үз мәнфәгатьләренең кысылуыннан.

Ләкин Нух галәйһиссәләм бу куркуларның беренчесенә: «Мин сезнең зыян-зәүрәтегездән курыкмыйм! Мин Аллаһка буйсынам!» – дип җавап бирә.

Икенче куркуга бәйле җавабында исә: «Сездән моның өчен бернинди түләү дә сорамыйм!» – ди. Аяти кәримәдә болай диелә:

وَمَا أَسْأَلُكُمْ عَلَيْهِ مِنْ أَجْرٍ إِنْ أَجْرِيَ إِلَّا عَلَى رَبِّ الْعَالَمِينَ. فَاتَّقُوا اللّٰهَ وَأَطِيعُونِ

**«**(Нух әйтте:) **Мин бит сездән моның өчен** (дингә өндәгәнем өчен) **түләү сорамыйм. Минем әҗерем – Аллаһта гына. Аллаһтан куркыгыз һәм миңа буйсыныгыз!»** («әш-Шугара», 109–110).

Ләкин Аның мондый дәгъватына колак салучы булмый. Хәзрәти Нухка кавеменнән бик азлар гына иман китерә. Үз улларыннан Сам, Һам һәм Яфәс иманга килә. Тагын бер улы – Кәнган исә атасының динен кире кага. Каве-

59. Ибне Ханбәл, «Әз-Зүһд», 50 б; Ибне әсир, «Әл-Камил», I, 69.

ме Нухны бөтен пәйгамбәрлеге дәвамында бик күп җәберли, күп газаплар китерә. Нух галәйһиссәләм кавеменең иза-җәфаларына 950 ел түзә. Ниһаять, җәбер-газапларына түзәрлеге калмыйча, Җәнабел-Хакка үзенең гаҗизлеген белдереп, догада ялвара.

Гасырлар дәвамында кайбер халыкларның пәйгамбәрләр китергән тәүхид гакыйдәсен кабул итмичә, һидәяттән мәхрүм калуларының төп сәбәпләре шул:

1. Хак диннәрдә дөньяда кылынган гамәлләр өчен саваплар һәм җәзалар бирелүгә бәйле рәвештә «ахирәт»кә ышану бар. Шуңа күрә кешеләр үзләре теләгәнчә гамәл кыла алмаслар. Дини хөкемнәргә ярашлы рәвештә, алар эш-гамәлләрен тәртипкә салырга тиеш.

Шулай итеп, Исламның барлыкка килүе белән мәҗүсиләрне борчуга салган беренче хәбәр «ахирәт» була. Аны «бөек хәбәр» дип атыйлар. Бу хәбәр аларны бик борчый. Коръәни-Кәримдә бу борчу-куркулары шул рәвешле белдерелә:

عَمَّ يَتَسَاءَلُونَ. عَنِ النَّبَإِ الْعَظِيمِ. الَّذِي هُمْ فِيهِ مُخْتَلِفُونَ

**«Алар бер-берләреннән нәрсә сорашалар? Бөек хәбәр турында. Ул ки, алар аның ышану-ышанмаулары хакында каршылыклы фикердә»** («ән-Нәбә», 1–3).

Мәҗүси кавемнәрдә исә көчле кешеләр зәгыйфьләрне даими кимсетеп, аларны үз нәфесләре теләгәнчә кол иткән. Зәгыйфьләрнең хакларын яклаган бер генә канун, кагыйдә дә булмый. Кавемдә барлык мәнфәгатьләр бары тик көчлеләр кулында туплана. Алар үзләренең кылган гамәлләренең ахирәттә берничек тә бәяләнмәячәкләренә инанган. Шуңа күрә хак диннәрдәге кебек ахирәткә ышану аларны бик нык хафага сала.

2. Хак диннәрдә билгеле бер тәртипкә салынган, билгеле бер ысулга нигезләнгән гыйбадәт тормышы бар. Мәҗүсиләрдә андый тәртип юк. Мәҗүсиләр потларны үз мәнфәгатьләренә ярашлы рәвештә, үзләренә ярдәмче буларак кабул иткән. Һәм аларны үзләрен саклаучы дип күзаллаган. Нәфес теләкләренә буйсынганга күрә, потпәрәстләр хак диннәрдәге тәртипле гыйбадәт тормышына буйсынырга теләмәгән.

3. Хак диннәрдә пәйгамбәрләр халыкка үрнәк шәхес (үсвә-и хасәнә) булган. Мәҗүсилеккә исә мондый үрнәккә иярү хас түгел. Потпәрәстләр нәфес теләкләре кушканча гамәл кылган. Әйтик, җаһилият чоры кавемендәге күп ирле хатыннар моңа бер мисал булып тора.

Кеше табигатенә инану ихтыяҗы хас. Хак Тәгаләне тапмаса яки хакыйкать аның өчен авыр булса, кеше хорафатларга ышана башлый. Инану, аң төпкелендә калып, чын чыганакка ирешә алмыйча, көферлек хаким итәр.

Ләкин инану, аң төпкеленнән илаһи вәхи юнәлешендә аң дәрәҗәсенә чыгып камилләшсә, иман барлыкка киләчәк.

4. Мәҗүсиләрнең көчле, бай һәм алдынгы кешеләре җәмгыятьтә бик гади тормышта яшәгән пәйгамбәрләрне һәм сәхабәләрне, тәкәбберлекләре сәбәпле, үзләреннән түбән күрү кабахәтлегенә төшәләр. Чөнки алар, иманлы, ләкин көчсез, зәгыйфь кешеләр белән бергә булсалар, җәмгыятьтәге дәрәҗәләре төшәчәк, дип уйлый.

5. Мәҗүсиләрнең һидәятенә киртә булган сәбәпләрнең тагын берсе – мал-мөлкәт, балалар кебек дөньяви мавыктыргычларның аларны гафләткә тартып, бик аяныч алдавы һәм аларның күңел күзләрен Хак Тәгаләдән каплауда.

Аяти кәримәдә болай диелә:

زُيِّنَ لِلنَّاسِ حُبُّ الشَّهَوَاتِ مِنَ النِّسَاءِ وَالْبَنِينَ وَالْقَنَاطِيرِ الْمُقَنْطَرَةِ مِنَ الذَّهَبِ وَالْفِضَّةِ وَالْخَيْلِ الْمُسَوَّمَةِ وَالْأَنْعَامِ وَالْحَرْثِ ذٰلِكَ مَتَاعُ الْحَيٰوةِ الدُّنْيَا وَاللّٰهُ عِنْدَهُ حُسْنُ الْمَآبِ

**«Күңел тартылган нәрсәләрне:** (аерым алганда) **хатыннарны, улларны, өем-өем җыелган алтын-көмешне, тамгаланган атларны, терлекне һәм игенлекләрне яралту кешеләр өчен зиннәтләндереп күрсәтелде. Бу – дөнья тормышының** (вакытлы) **нәрсәләре. Яхшы кайтачак урын исә – Аллаһ хозурында»** («Әли Гыймран», 14).

Нух галәйһиссәләм мәҗүси кавеменең начар ниятләрен фаш итеп, аларга мөрәҗәгать белән чыга:

وَاتْلُ عَلَيْهِمْ نَبَأَ نُوحٍ إِذْ قَالَ لِقَوْمِهِ يَا قَوْمِ إِنْ كَانَ كَبُرَ عَلَيْكُمْ مَقَامِي
وَتَذْكِيرِي بِآيَاتِ اللّٰهِ فَعَلَى اللّٰهِ تَوَكَّلْتُ فَأَجْمِعُوا أَمْرَكُمْ وَشُرَكَاءَكُمْ
ثُمَّ لَا يَكُنْ أَمْرُكُمْ عَلَيْكُمْ غُمَّةً ثُمَّ اقْضُوا إِلَيَّ وَلَا تُنْظِرُونِ

**«Аларга Нухның хәбәрен укы. Менә ул кавеменә әйтте: “И, кавемем! Әгәр минем торган урыным һәм Аллаһның аятьләренә өндәвем сезгә авырга килсә, мин Аллаһка гына тәвәккәл кылдым. Сез уйдырмаларыгыз белән бергәләп эшегезне бер җайга китерегез, шуннан эшегез сезгә яшерен булмасын, шуннан соң мине нишләтергә теләгәнегезгә карар бирегез һәм миңа кичектерү бирмәгез”»** («Йунус», 71).

Һичшиксез, Нух галәйһиссәләмнең бу сүзләре аның Раббысына бар күңеле белән бирелгәнлеген күрсәтә.

**Бәдбәхет кавемнең газап соравы**

Нух галәйһиссәләмгә дәгъват эшенең беренче елларында, иман китергәннәрдән кала, башкалар кушылмый. Өстәвенә, кавеменең аңа һәм мөселманнарга карата кылган җәфа-газаплары да чиктән аша. Хәтта сукырларча кыюлык белән алар илаһи газапны үзләре сорап алуга кадәр азгынлыкка чыга:

قَالُوا يَا نُوحُ قَدْ جَادَلْتَنَا فَأَكْثَرْتَ جِدَالَنَا فَأْتِنَا بِمَا تَعِدُنَا إِنْ كُنْتَ مِنَ الصَّادِقِينَ

**«Алар: “И, Нух! Син безнең белән тартыштың һәм тартышуыңны арттыра бардың. Әгәр син тугры кешеләрдән булсаң, вәгъдә иткәннәреңне** (газабыңны) **китер инде”, – диделәр»** («Һуд», 32).

Нух галәйһиссәләм, үзен түбәнсетеп, иманга өндәвен ялган санап, «әйдә, вәгъдә иткән газабыңны күрсәт!» диюләренә карамастан, Аллаһның кодрәте һәм яклавы турында залим кавеменең исенә төшерә:

قَالَ إِنَّمَا يَأْتِيكُمْ بِهِ اللَّهُ إِنْ شَاءَ وَمَا أَنْتُمْ بِمُعْجِزِينَ. وَلَا يَنْفَعُكُمْ نُصْحِي إِنْ أَرَدْتُ أَنْ أَنْصَحَ لَكُمْ إِنْ كَانَ اللَّهُ يُرِيدُ أَنْ يُغْوِيَكُمْ هُوَ رَبُّكُمْ وَإِلَيْهِ تُرْجَعُونَ

**«**(Нух) **әйтте: “Теләсә, аны сезгә Аллаһ кына китерә ала. Әмма сез (Аллаһны) берничек тә гаҗиз калдыра алмаячаксыз. Аллаһ сезне адаштырырга теләгән булса, мин сезгә игелек кылырга** (үгетләргә) **теләсәм дә, киңәшләрем сезгә файда китермәс.** (Чөнки) **Ул – Раббыгыз. Һәм Аңа гына кайтарылачаксыз”»** («Һуд», 33–34).

Аллаһ Тәгалә, бу кавемнең имансызлыгы сәбәпле, Хәзрәти Нухны юатыр өчен, шундый вәхи иңдерә:

لَنْ يُؤْمِنَ مِنْ قَوْمِكَ إِلَّا مَنْ قَدْ آمَنَ فَلَا تَبْتَئِسْ بِمَا كَانُوا يَفْعَلُونَ

**«Синең кавемеңнән** (шушы вакытка кадәр) **иман китерүчеләрдән башка берәү дә һич инанмаячак. Син алар кылган нәрсәләр** (гөнаһлар) **өчен борчылма!»** («Һуд», 36).

Ниһаять, илаһи газапның беренче башлангыч хәбәре сыйфатында, Җәнабел-Хак әлеге һич баш бирмәгән азгын кавемгә кырык ел буе яңгыр яудырмый тора. Аларның мал-утарлары кырылып бетә. Балалары тумас була. Чарасыз калып, Хәзрәти Нухка мөрәҗәгать итәләр. Ул:

«Ширектән ваз кичегез, сезнең өчен дога кылырмын!» – ди.

فَقُلْتُ اسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ إِنَّهُ كَانَ غَفَّارًا. يُرْسِلِ السَّمَاءَ عَلَيْكُمْ مِدْرَارًا.
وَيُمْدِدْكُمْ بِأَمْوَالٍ وَبَنِينَ وَيَجْعَلْ لَكُمْ جَنَّاتٍ وَيَجْعَلْ لَكُمْ أَنْهَارًا

**«**(Аннары Нух Җәнабел-Хак түбәндәгечә ялвара: “Йә Раббы, кавемемә) **әйттем: “Раббыгыздан ярлыкау сорагыз. Һичшиксез, Ул – Гафу итүче.** (Ярлыкау сорагыз да) **күкне өстегезгә мул** (яңгыр) **яуган бер хәлдә җибәрер. Маллар һәм ир балалар белән сезгә ярдәм итәр, сезнең өчен бакчалар үстерер һәм сезнең өчен елгалар булдырыр”»** («Нух», 10–12).

Мукәтил ибне Сөләйман рәхмәтуллаһи галәйһи: «Бу аятьләрдән соң яңгыр сорап дога кылганда, тәүбә-истигъфар уку барлыкка килә», – дип аңлата.

Габдуллаһ ибне Габбастан тапшырыла:

*«Бер кеше күп тапкыр тәүбә итсә, Аллаһ Җәллә Җәләлүһү аны теләсә нинди кыенлыклардан коткарыр. Теләсә нинди читенлектән чыгу юлын насыйп итәр. Аны һич өмет итмәгән җирдән ризыкландырыр»* (Ибне Маҗә, «Зүһд», 30).

Нух галәйһиссәләм кавемен кисәтүне һәм аңа нәсыйхәт бирүен түбәндәгечә дәвам итә:

مَا لَكُمْ لَا تَرْجُونَ لِلَّهِ وَقَارًا. وَقَدْ خَلَقَكُمْ أَطْوَارًا. أَلَمْ تَرَوْا كَيْفَ
خَلَقَ اللَّهُ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ طِبَاقًا. وَجَعَلَ الْقَمَرَ فِيهِنَّ نُورًا وَجَعَلَ الشَّمْسَ
سِرَاجًا. وَاللَّهُ أَنبَتَكُمْ مِنَ الْأَرْضِ نَبَاتاً. ثُمَّ يُعِيدُكُمْ فِيهَا وَيُخْرِجُكُمْ إِخْرَاجًا.
وَاللَّهُ جَعَلَ لَكُمُ الْأَرْضَ بِسَاطًا. لِتَسْلُكُوا مِنْهَا سُبُلًا فِجَاجًا

**«Нишләп сез Аллаһның бөеклегенә ышанмыйсыз? Ул бит сезне төрле рәвешләр буларак яралтты. Аллаһның җиде күкне катлар хәлендә** (бер-берсе белән ярашлы рәвештә) **ничек яралтканын күрмәдегезме? Алардагы айны бер нур итте, кояшны исә бер кандил итте. Аллаһ сезне җирдән үсемлек** (үстергән) **кебек үстерде. Шуннан соң аның эченә кайтарачак һәм сезне бер чыгарылыш белән чыгарачак. Аллаһ җирне, аның өстендә киң юлларда йөрсеннәр, дип, сезнең өчен түшәк итте»** («Нух», 13–20).

Ләкин бу ахмак мәҗүси кавем хикмәт тулы нәсыйхәтләргә колак салмый.

قَالَ نُوحٌ رَبِّ إِنَّهُمْ عَصَوْنِي وَاتَّبَعُوا مَنْ لَمْ يَزِدْهُ مَالُهُ وَوَلَدُهُ إِلَّا خَسَارًا.
وَمَكَرُوا مَكْرًا كُبَّارًا. وَقَالُوا لَا تَذَرُنَّ آلِهَتَكُمْ وَلَا تَذَرُنَّ وَدًّا وَلَا سُوَاعًا وَلَا
يَغُوثَ وَيَعُوقَ وَنَسْرًا. وَقَدْ أَضَلُّوا كَثِيرًا وَلَا تَزِدِ الظَّالِمِينَ إِلَّا ضَلَالًا

**«**(Үгетләре файда бирмәгәч) **Нух әйтте: “И, Раббым! Алар миңа карыштылар һәм малы белән баласы зарарларын гына арттырган нәрсәгә иярделәр. Алар зур хәйлә кордылар.** (Раббым!) **Алар** (бер-берсенә)**: “Илаһларыгызны ташламагыз, Вәддне, Сүвагны, Ягусны, Ягукны, Нәср-**

**не кире какмагыз!” – диделәр. Һичшиксез,** (шул рәвешле) **алар бик күпләрне юлдан яздырдылар.** (Раббым!) **Залимнәрнең адашуларыннан башка берниләрен дә арттырма!»** («Нух», 21–24).

Нухка ишарәләп, бер ата угылына: «Кара аны, моңа ышанма!» – ди.

Угылы исә атасының таягын ала да, Нух галәйһиссәләмнең башына сугып, аны канга батырып калдыра. Нух галәйһиссәләм исә: «Йә Раббым! Әгәр хәер теләсәң, һидәяткә ирештер! Югыйсә Син аларны хөкем иткәнчегә кадәр миңа сабырлык бир! Чөнки Син – хөкем итүчеләрнең иң хәерлесе!» – ди.

Ләкин золымнар шактый арта. Аларга каршы түзәр чама калмый. Шуннан соң Нух галәйһиссәләм:

فَدَعَا  رَبَّهُ أَنِّي مَغْلُوبٌ فَانْتَصِرْ

**«Ул Раббысына дога кылды: “**(Йә, Раббы)**, мин җиңелдем. Син миңа ярдәм ит!”»** («әл-Камәр», 10).

Нух галәйһиссәләмнең озак еллар дәвамында дингә өндәвенә карамастан, аңа бик аз кеше генә ышана. Бер нәсел үлеп киткәндә, үзләреннән соң калган нәселләргә Нухка иман китермәскә, аңа кире кагырга, аңа каршы көрәшергә васыять итәләр. Аталар, үсеп җитеп балигъ булган балаларын:

«Гомерегез булган кадәр Нухка беркайчан да инанмаячаксыз!» – дип үгетлиләр. Холыклары бөтенләй бозылган, иманны һәм хакка иярүне кире кагырлык бер хәлгә килгән була. Шул сәбәпле, Нух галәйһиссәләм үз шикаятендә болай ди:

وَقَالَ نُوحٌ رَبِّ لَا تَذَرْ عَلَى الْأَرْضِ مِنَ الْكَافِرِينَ  دَيَّارًا. إِنَّكَ إِنْ تَذَرْهُمْ
يُضِلُّوا عِبَادَكَ وَلَا يَلِدُوا إِلَّا فَاجِرًا  كَفَّارًا.رَبِّ اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ وَلِمَنْ دَخَلَ
بَيْتِيَ مُؤْمِنًا وَلِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَلَا تَزِدِ الظَّالِمِينَ إِلَّا تَبَارًا

**«И, Раббым! Җир йөзендә кяферләрдән беркемне дә калдырма! Чөнки Син аларны калдырсаң, Синең колларыңны адаштырырлар. Алар кяфер һәм гөнаһлы кешеләрдән башка беркем дә тудырмаслар. Мине дә, ата-анамны да, өемә иманлы буларак кергән кешеләрне** (гаиләмнән иман китергәннәрне) **дә, иманлы ирләр белән иманлы хатыннарны да ярлыка! Залимнәргә исә һәлакәттән башка бернәрсәне дә арттырма!»** («Нух», 26–28).

Шушы ялварудан соң Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Хәзрәти Нухка бер көймә (кораб) ясарга куша:

وَاصْنَعِ الْفُلْكَ بِأَعْيُنِنَا وَوَحْيِنَا وَلَا تُخَاطِبْنِي فِي الَّذِينَ ظَلَمُوا إِنَّهُمْ مُغْرَقُونَ

**«Безнең саклавыбыз белән** (күзебез каршында) **һәм вәхиебез белән көймә яса. Золым кылган кешеләр өчен исә Миннән сорама. Һичшиксез, алар суга батырылачаклар»** («Һуд», 37).

Кавеме Нух галәйһиссәләмнең кораб ясавын да көлкегә калдыра.

Аяти кәримәләрдә әйтелә:

وَيَصْنَعُ الْفُلْكَ وَكُلَّمَا مَرَّ عَلَيْهِ مَلأٌ مِنْ قَوْمِهِ سَخِرُوا مِنْهُ قَالَ إِنْ تَسْخَرُوا مِنَّا فَإِنَّا نَسْخَرُ مِنْكُمْ كَمَا تَسْخَرُونَ. فَسَوْفَ تَعْلَمُونَ مَنْ يَأْتِيهِ عَذَابٌ يُخْزِيهِ وَيَحِلُّ عَلَيْهِ عَذَابٌ مُقِيمٌ

**«Ул** (Нух) **көймә ясады, кавеменең олуглары исә үткән саен аны мыскыл иттеләр. Ул әйтте: “Сез безне мыскыл итсәгез,** (белеп торыгыз) **сез мыскыл иткәнегез кебек, без дә сезне мыскыл итәрбез. Сез кимсетүле газап кемгә киләчәген, даими газап кемгә киләчәген** (тиздән) **беләчәксез”»** («Һуд», 38–39).

Хак һәм хакыйкатькә каршы калебләре сукырайган халык төнлә көймәгә ут төртеп яндырырга тели. Яндыра алмагач: «Бу синең сихерең!» – диләр. Көймәне пычраталар. Бераз вакыт узгач, кавем халкы корчаңгы авыруына дучар ителә. Дәвалану өчен үз пычракларын йөзләренә сөртергә мәҗбүр булалар. Җәнабел-Хак аларны бу галәмәтләр белән кисәткән хәлдә дә, акылга килмиләр, гафләт йокысыннан берничек тә уянмыйлар.

**Туфан – җибәрелгән газап**

Нух галәйһиссәләмнең иман китергәннәр белән бергә төзегән корабы авыр шартларга чыдый алырлык итеп, каты агачтан ясалган була. Риваятьләрдә әйтелгәнчә, ул өч катлы итеп, ике яки дүрт ел дәвамында төзелә, эчендә ут ягып, пар белән эшли торган итеп ясала.

Ибне Габбастан тапшырылганча, корабка сиксән кеше утыра. Адәм галәйһиссәләмнең Җәбраил тарафыннан китерелгән «табут»ы (сандыгы) да көймәгә алына һәм ирләр белән хатыннар арасына куела (Карагыз: Ибне Сәгъд, I, 41).

Аяти кәримәдә әйтелә:

حَتَّى إِذَا جَاءَ أَمْرُنَا وَفَارَ التَّنُّورُ قُلْنَا احْمِلْ فِيهَا مِنْ كُلٍّ زَوْجَيْنِ اثْنَيْنِ وَأَهْلَكَ إِلَّا مَنْ سَبَقَ عَلَيْهِ الْقَوْلُ وَمَنْ آمَنَ وَمَا آمَنَ مَعَهُ إِلَّا قَلِيلٌ

**«Әмеребез килгәч һәм тандыр кайнап чыккач** (фарат-тәннур – эшләр кызыр, сулар кайный-кабара башлагач)**, Без** (Нухка)**: “Һәрбереннән икешәрне һәм, сиңа каршы сүз әйтелгәннәрдән тыш, гаиләңне һәм иман китергән кешеләрне керт”, – дидек. Аның белән исә бик аз гына кеше иман итте»** («Һуд», 40).

Аятьтәге «тәннур» сүзе сүзлектә «мич» дип бирелә. Башка мәгънәләре дә бар. Шуңа нигезләнеп, кайбер галимнәр Нух галәйһиссәләм көймәсенең ут ягып кайнатылган бер казан механизмына ия, ягъни пар ярдәмендә эшләгән көймә булганлыгын белдерәләр.

Башка бер аяти кәримәдә көймәгә утыручылар турында шундый мәгълүмат бирелә:

فَأَوْحَيْنَا إِلَيْهِ أَنِ اصْنَعِ الْفُلْكَ بِأَعْيُنِنَا وَوَحْيِنَا فَإِذَا جَاءَ أَمْرُنَا وَفَارَ التَّنُّورُ
فَاسْلُكْ فِيهَا مِنْ كُلٍّ زَوْجَيْنِ اثْنَيْنِ وَأَهْلَكَ إِلَّا مَنْ سَبَقَ عَلَيْهِ الْقَوْلُ مِنْهُمْ
وَلَا تُخَاطِبْنِي فِي الَّذِينَ ظَلَمُوا إِنَّهُمْ مُغْرَقُونَ

**«Без аңа: “Безнең күзәтүебез белән** (саклавыбызда) **һәм белдергәнебезчә көймә яса. Әмеребез килгәч һәм сулар кайнап күтәрелә башлагач, һәрбереннән берәр пар һәм гаиләңне аңа керт. Әмма алар арасыннан сүзем алдан әйтелгәннәрне түгел. Золым кылучылар хакында Миннән сорама. Һичшиксез, алар суга батырылачак”»** («әл-Мүэминүн», 27).

Көймәгә хайваннар да алынган. Риваять ителгәнчә, Нух галәйһиссәләм елан белән чаянны көймәгә кертергә теләми. Алар: «Синең исемеңне зикер итүчеләргә зарар китермәячәкбез», – дип ант итә.

Шул сәбәпле, чаян һәм елан белән очрашкан кешегә:

سَلَامٌ عَلَى نُوحٍ فِي الْعَالَمِينَ

**«Барлык галәмнәр эчендә Нухка сәлам булсын!»** аяти кәримәсен («әс-Сәффат», 79) ихлас ният белән укыса, аларның зарарыннан сакланган булыр.

Нух галәйһиссәләм, Аллаһның әмерен үтәп, көймәгә алынасы барлык җан ияләрен дә менгезеп һәм кирәкле әзерлекләрне башкарып бетергәч, туфан галәмәтләре күренә башлый. Аяти кәримәдә бу хәлләр шулай тасвирлана:

فَفَتَحْنَا أَبْوَابَ السَّمَاءِ بِمَاءٍ مُنْهَمِرٍ. وَفَجَّرْنَا الْأَرْضَ عُيُونًا فَالْتَقَى الْمَاءُ عَلَى أَمْرٍ قَدْ قُدِرَ

**«Без күкнең су (яңгыр) коелган капкаларын ачтык. Җирне ярып, аннан чишмәләр аттырдык, шулай итеп сулар тәкъдир ителгән бер эш (туфан афәте) өчен кушылдылар»** («әл-Камәр», 11–12).

Нух галәйһиссәләмнең улы Кәнган көймәгә утырмый. Хәзрәти Нух соңгы тапкыр аңа нәсыйхәт белән мөрәҗәгать итсә дә, файдасы тими. Коръәни-Кәримдә бу вакыйга шулай сурәтләнә:

وَنَادَى نُوحٌ ابْنَهُ وَكَانَ فِي مَعْزِلٍ يَا بُنَيَّ ارْكَبْ مَعَنَا وَلَا تَكُنْ مَعَ الْكَافِرِينَ. قَالَ سَآوِي إِلَى جَبَلٍ يَعْصِمُنِي مِنَ الْمَاءِ قَالَ لَا عَاصِمَ الْيَوْمَ مِنْ أَمْرِ اللَّهِ إِلَّا مَنْ رَحِمَ

**«Нух аерым бер җирдә** (көймәдән еракта) **булган улына: "И, улым! Безнең белән бергә утыр, кяферләр белән бергә булма", – дип эндәште. Ул исә: "Мине судан саклаячак бер тауга сыеначакмын", – диде. Ул** (Нух)**: "Бүген,** (Аллаһ) **рәхмәт иткән кешедән башка, Аллаһның әмереннән** (газабыннан) **котылган берәү дә юк", – диде...»** («Һуд», 42–43).

Угылына биргән үгет-нәсыйхәтләр файда китермәгәч, Нух галәйһиссәләм Раббысына юнәлеп:

وَنَادَى نُوحٌ رَبَّهُ فَقَالَ رَبِّ إِنَّ ابْنِي مِنْ أَهْلِي وَإِنَّ وَعْدَكَ الْحَقُّ وَأَنْتَ أَحْكَمُ الْحَاكِمِينَ

**«И, Раббым! Һичшиксез, улым бит – минем гаиләмнән. Синең вәгъдәң хак, һәм Син – хакимнәрнең иң гадел хөкем бирүчесе»**, – дип ялвара («Һуд», 45).

Үз кавеменә бәддога иткәннән соң, угылына дога кылып, Нух галәйһиссәләм хаталана. Чөнки Аллаһ Җәллә Җәләлүһү аны залимнәр өчен дога кылудан тыйган була. Бу хәлдә Нух җаһилләр исәбеннән булмас өчен, илаһи кисәтү килә:

قَالَ يَا نُوحُ إِنَّهُ لَيْسَ مِنْ أَهْلِكَ إِنَّهُ عَمَلٌ غَيْرُ صَالِحٍ فَلَا تَسْأَلْنِ مَا لَيْسَ لَكَ بِهِ عِلْمٌ إِنِّي أَعِظُكَ أَنْ تَكُونَ مِنَ الْجَاهِلِينَ. قَالَ رَبِّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ أَنْ أَسْأَلَكَ مَا لَيْسَ لِي بِهِ عِلْمٌ وَإِلَّا تَغْفِرْ لِي وَتَرْحَمْنِي أَكُنْ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«**(Аллаһ) **әйтте: "И, Нух! Ул – синең гаиләңнән түгел. Һичшиксез, бу – килешле булмаган бер гамәл. Син үзең белмәгән нәрсә турында Миннән сорама. Белмәүчеләрдән булма, дип, Мин сиңа вәгазь кылам".** (Кылган хатасын аңлап, Нух) **әйтте: "И, Раббым! Мин белмәгән бернәрсәне Синнән соравымнан Сиңа сыенам. Әгәр мине ярлыкамасаң һәм мине кызганмасаң, мин зарар күрүчеләрдән булырмын"»** («Һуд», 46–47).

Риваять ителгәнчә, Нух галәйһиссәләм бу ялгышуы аркасында бик күп елап, күз яшьләре түккәнгә, аңа «Нух» исеме бирелә. Нух галәйһиссәләм, тәүбә итеп, хатасыннан шунда ук ваз кичә. Әмма углы көферлектән кире кайтмый һәм ахыр чиктә:

وَحَالَ بَيْنَهُمَا الْمَوْجُ فَكَانَ مِنَ الْمُغْرَقِينَ

**«Дулкыннар араларына керде һәм улы да суга батучылардан булды»** («Һуд», 43).

Бары тик Хәзрәти Нухка, Аңа иман китерүчеләргә һәм көймәгә алынган мәхлукатка гына илаһи котылу насыйп була. Алар утырган кораб тау кадәр дулкыннар арасында йөзеп йөри. Аллаһ Тәгалә болай ди:

وَهِيَ تَجْرِي بِهِمْ فِي مَوْجٍ كَالْجِبَالِ

**«Ул** (көймә) **таулар кебек дулкыннар эчендә алар белән кузгалып китkәч...»** («Һуд», 42).

تَجْرِي بِأَعْيُنِنَا جَزَاءً لِمَنْ كَانَ كُفِرَ. وَلَقَدْ تَرَكْنَاهَا آيَةً فَهَلْ مِنْ مُدَّكِرٍ. فَكَيْفَ كَانَ عَذَابِي وَنُذُرِ

**«Ул Безнең саклавыбыз белән йөзеп йөрде. Инкяр ителгән кешегә** (Нухка) **җитәрлек әҗер итеп. Без аны бер билге буларак калдырдык, ләкин үгет алучылар бармы? Минем газабым һәм кисәтүләрем нинди булды соң!»** («әл-Камәр», 14–16).

**Суларның чигенүе**

Көймәгә менгәнче үк үзенә өйрәтелгән шушы дога ярдәмендә Хәзрәти Нух галәйһиссәләм сау-сәламәт кала:

فَقُلِ الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي نَجَّينَا مِنَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ. وَقُلْ رَبِّ أَنْزِلْنِي مُنْزَلًا مُبَارَكًا وَأَنْتَ خَيْرُ الْمُنْزِلِينَ

**«Барча мактаулар – Аллаһка, Ул безне залимнәр кавеменнән коткарды. И, Раббым! Мине бәрәкәтле бер урынга урнаштыр. Син бит урнаштыручыларның иң яхшысы, дип әйт»** («әл-Мүэминүн», 28–29).

Риваятьтә әйтелгәнчә, туфан рәҗәб аеның беренче көнендә башланып, кораб алты ай су өстендә йөзеп йөри. Аннан соң Аллаһ Тәгалә җиргә һәм күкләргә әмер итте:

وَقِيلَ يَا أَرْضُ ابْلَعِي مَاءَكِ وَيَا سَمَاءُ أَقْلِعِي

**«”И, җир! Суны сеңдер! И, күк! Син дә тот!” – диелде»** («Һуд», 44).

Бу илаһи әмер нәтиҗәсендә сулар чигенә һәм көймә 10 нчы Мөхәррәм, ягъни Гашура көнендә Җүди тавына төшеп утыра. Аннан соң Нух галәйһиссәләмгә Җәнабел-Хак тарафыннан хәбәр җибәрелә:

قِيلَ يَا نُوحُ اهْبِطْ بِسَلَامٍ مِنَّا وَبَرَكَاتٍ عَلَيْكَ وَعَلَى أُمَمٍ مِمَّنْ
مَعَكَ وَأُمَمٌ سَنُمَتِّعُهُمْ ثُمَّ يَمَسُّهُمْ مِنَّا عَذَابٌ أَلِيمٌ

**«Әйтелде: “И, Нух! Синңа һәм синең белән булган өммәтләргә Бездән бер иминлек һәм бәрәкәтләр белән** (көймәдән) **төш. Өммәтләрне исә** (дөньяда) **башта рәхәт яшәтәчәкбез, шуннан соң аларга Бездән тилмерткеч бер газап кагылачак”»** («Һуд», 48).

Хәзрәти Нух галәйһиссәләм белән мөэминнәр котылып кала. Аяти кәримәләрдә әйтелә:

فَأَنجَيْنَاهُ وَمَنْ مَعَهُ فِي الْفُلْكِ الْمَشْحُونِ

**«Без аны һәм янында булганнарны тулы көймә эчендә коткардык»** («әш-Шугара», 119).

وَجَعَلْنَاهُمْ خَلَائِفَ وَأَغْرَقْنَا الَّذِينَ كَذَّبُوا بِآيَاتِنَا فَانْظُرْ كَيْفَ كَانَ عَاقِبَةُ الْمُنذَرِينَ

**«...Аларны көймәдә коткардык** (башкалар урынына күчердек)**, аларны хәлифәләр иттек һәм безнең аятьләребезне ялганга санаучыларны суга батырдык. Ул кисәтелгәннәрнең** (ләкин ышанмаганнарның) **ахыры нинди булганын кара!»** («Йунус», 73).

Дөньяда – афәт, ахирәттә – аянычлы газап... Җәнабел-Хак залимнәрнең язмышын аяти кәримәдә шул рәвешле тасвирлый:

مِمَّا خَطِيئَاتِهِمْ أُغْرِقُوا فَأُدْخِلُوا نَارًا فَلَمْ يَجِدُوا لَهُمْ مِنْ دُونِ اللَّهِ أَنْصَارًا

**«Гөнаһлары өчен алар суга батырылдылар һәм утка кертелделәр, ләкин үзләренә Аллаһтан башка ярдәмчеләр таба алмадылар»** («Нух», 25).

Куртуби тәфсирендә Хәзрәти Хөсәен радыйаллаһу ганһедән тапшырылган хәдис-шәриф китерелә:

*«Өммәтем, көймәгә менгәндә, “бисмиллаһ” әйтеп:*

بِسْمِ اللَّهِ مَجْرِيهَا وَمُرْسِيهَا إِنَّ رَبِّي لَغَفُورٌ رَحِيمٌ

***“Аның йөзүе дә, туктавы да – Аллаһның исеме белән. Һичшиксез, минем Раббым – Гафу итүче, Рәхимле”»*** («Һуд», 41)

аяте белән бергә,

وَمَا قَدَرُوا اللَّهَ حَقَّ قَدْرِهِ وَالْأَرْضُ جَمِيعًا قَبْضَتُهُ يَوْمَ الْقِيَامَةِ
وَالسَّماوَاتُ مَطْوِيَّاتٌ بِيَمِينِهِ سُبْحَانَهُ وَتَعَالَى عَمَّا يُشْرِكُونَ

**«”Алар Аллаһны тиешле олылау белән олыламадылар. Югыйсә, Кыямәт көнендә бөтен җир Аның учында. Күкләр дә Аның кодрәте белән**

**төрелгәннәр. Ул пакь! Алар ширек кушкан нәрсәләрдән Ул өстен”»**, аятен («әз-Зүмәр», 67) укыса, суга батудан котылырлар» (Куртуби, IX, 37).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, юлга чыкканда, хайванның өстенә яхшылап менеп атлангач, өч тапкыр тәкбир әйткән һәм:

...سُبْحانَ ي سَخَّرَ لَنَا هَذَا وَمَا كُنَّا لَهُ مُقْرِنِينَ الَّذِ وَإِنَّا إِلَى رَبِّنَا لَمُنقَلِبُونَ

**«Моны безгә буйсындырган Зат (Аллаһ) пакь (Аны тәсбих итәбез) Безнең моңа көчебез җитмәс иде. Һичшиксез, без – Раббыбызга кайтучыларбыз!»** – аятьләрен укый («әз-Зүхруф», 13–14) һәм соңыннан шулай итеп дога кылган:

اَللَّهُمَّ إِنَّا نَسْأَلُكَ فِي سَفَرِنَا هَذَا الْبِرَّ وَالتَّقْوَى وَمِنَ الْعَمَلِ مَا تَرْضَى. اَللَّهُمَّ هَوِّنْ عَلَيْنَا سَفَرَنَا هَذَا وَاطْوِ عَنَّا بُعْدَهُ. اَللَّهُمَّ أَنْتَ الصَّاحِبُ فِي السَّفَرِ وَالْخَلِيفَةُ فِي الأَهْلِ. اَللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ مِنْ وَعْثَاءِ السَّفَرِ وَكَآبَةِ الْمَنْظَرِ وَسُوءِ الْمُنْقَلَبِ فِي الْمَالِ وَالأَهْلِ

*«И, Аллаһым! Без бу сәфәребездә Синнән яхшылык һәм тәкъвалык сорыйбыз, шулай ук безгә Син риза булырлык гамәлләр кылырга насыйп итүеңне телибез. И, Аллаһым! Бу сәфәребезне уңышлы ит һәм ерак араны якын кыл! И, Аллаһым! Сәфәрдә – ярдәмчем, өйдә калган бала-чагаларымның саклаучысы Син. И, Аллаһым! Юлның авырлыкларыннан, төшенкелеккә бирелдерә торган нәрсәләр белән очрашудан һәм кайтуыбызга мал-мөлкәтебездә, бала-чагабызда начар хәлләр күрүдән Сиңа сыенабыз».*

Пәйгамбәребез, сәфәрдән кайткач та шул ук сүзләрне кабатлап, моны өстәп әйтә торган була:

آيِبُونَ تَائِبُونَ عَابِدُونَ لِرَبِّنَا حَامِدُونَ

*«Без – сәфәрдән кайткан, тәүбә иткән, кол булган һәм Раббыбызга хәмед иткән кешеләр»* (Мөслим, «Хаҗ», 425; Әбү Давыд, «Җиһад», 72).

Галимнәр фикеренчә, туфан бар кешелек өчен гомуми булган. Җир йөзенең һәр тарафын су каплаган. Нишанҗызадә Мухйиддин Мәхмәд «Миргат әл-Каинат» исемле китабында болай ди:

«Көймә җиргә утыруга, сиксән кеше “Мәдинәтүс-Сәманин” шәһәрен сала. Бу шәһәрне “Сук әл-Сәманин” дип тә атаганнар».

Кешелекнең икенче тапкыр күбәю-артуы менә шушы сиксән кешедән башлана. Нух галәйһиссәләмнең олы угылы Сәм акыллы һәм тәкъва кеше була. Атасыннан соң ул вәкилгә әйләнә. Хәзрәти Нухның хәер-догаларына

лаек була. Тәкъва кешеләрнең күпчелеге аның нәселеннән килә. Гарәпләр һәм фарсылар аның нәселеннән үрчи.

Икенче угылы Хамнан – һинд, хәбәш (эфиоп) һәм африкалылар; Яфәстән – русларның, славян һәм төркиләрнең килеп чыгышы фараз кылына. Азиялеләр һәм Беринг бугазыннан кичүләре фараз кылынган җирле америкалылар (индеецлар) да аның нәселеннән ишәйгән. Ләкин, вакытлар узу белән, дини хакыйкатьләр янәдән онытыла. Кешеләр йолдызларга, кояшка һәм һәйкәлләргә гыйбадәт кыла башлый.

Мөфәссир Фәхреддин әр-Разыйның сөйләвенчә, Коръәни-Кәримдә Нух галәйһиссәләмнең үз кавеме эчендә 950 ел газаплы тормыш кичерүе, иза чигеп яшәве турында белдерелүе Рәсүлүллаһны юату өчен була. Нух галәйһиссәләмнең газап һәм җәфаларга озак еллар буе түзүе өммәт өчен камил сабырлык үрнәгенә әйләнә.

**Гашура көне**

Көймә мөхәррәм аеның 10 нчы көнендә, Гашура көне буларак билгеле көнне, исән-имин килеш Җуди тавына туктаганнан соң, Хәзрәти Нух һәм мөселманнар, шөкер итеп, ураза тоталар. Калган ризыклардан гашура пешерәләр. Шул сәбәпле, бу көнне (мөхәррәмнең 10ында) сәдака бирү, тәмле ризыклар тарату һәм ураза тоту сөннәт санала.

Әбү Һүрайра радыйаллаһу ганһе Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять кыла:

*«Рамазаннан соң иң саваплы ураза Аллаһ ае саналган мөхәррәмдә тотыла»* (Мөслим, «Сыям», 202).

Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе Хәзрәти Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять кыла:

«Бер кеше килеп, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләменнән: “Йә Рәсүлүллаһ! Рамазаннан соң кайсы айда ураза тотуыма әмер итәрсез?” – дип сораган.

Пәйгамбәребез:

*“Әгәр рамазаннан соң ураза тотсаң, мөхәррәмдә тот. Чөнки ул – Аллаһның ае. Анда бер көн бар, Аллаһ бер кавемнең тәүбәсен шул көнне кабул итте. Башка кавемнәрнең тәүбә һәм теләкләрен дә шул көнне кабул итәр”*, – дип җавап биргән» (Тирмизи, «Саум», 40/741).

Ул көн – Гашура көне, ә кавем дигәне – Хәзрәти Муса галәйһиссәләмнең кавеме Бәни Исраил була. Шуңа күрә яһүдиләр Гашура көнен бәйрәм итеп сайлаганнар, бу көнне ирләр һәм хатыннар барысы да матур киенүне гадәт иткән.

Шулай ук, ул көнне Хәзрәти Муса галәйһиссәләмнең Аллаһка шөкер итү нияте белән ураза тотуына нигезләнеп, бер төркем яһүдиләр, пәйгамбәрләренә ияреп, Гашура көнен уразада үткәрә.

Бу көннең фазыйләтләре турында түбәндәгеләр риваять кылына:

Җәнабел-Хак Адәм галәйһиссәләмнең тәүбәсен шушы көнне кабул итте һәм аны бу көнне «Сафиййуллаһ» кылды;

Идрис галәйһиссәләмне бу көнне югары дәрәҗәгә күтәрде;

Хәзрәти Нухны шушы көнне көймәдән чыгарды;

Хәзрәти Ибраһимны уттан бу көнне коткарды;

Тәүратны Муса галәйһиссәләмгә бу көнне иңдерде;

Хәзрәти Йосыфны төрмәдән бу көнне коткарды;

Хәзрәти Ягъкубның күрү сәләтен бу көнне кайтарды;

Хәзрәти Әйюбка бу көнне шифасын насыйп итте;

Хәзрәти Юнысны балык карыныннан бу көнне чыгарды;

Кызыл диңгезне урталай ярып ачып, шушы көнне Бәни Исраил кавемен саклап калды;

Давыд галәйһиссәләмне бу көнне кичерде;

Хәзрәти Сөләйманга бу көнне мөлкәт һәм солтанат бирде;

Хәзрәти Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең кылган һәм кылачак гөнаһларын бу көнне гафу итте.

Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмәдән тапшырыла:

«Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылганда, яһүдиләрнең ураза тотканнарын күрә. Сәбәбен сорагач, яһүдиләр: “Бүген хәерле, файдалы һәм бөек көн. Аллаһ бу көнне Мусаны һәм Бәни Исраил кавемен дошманнарыннан коткарып, Фиргавен һәм аның иярченнәрен диңгез эчендә калдырып батырган. Аллаһка шөкер итеп, Муса бу көнне ураза тотты, без дә тотабыз”», – дип әйтә.

Шуннан соң Пәйгамбәребез:

*«Без Мусага иярү ягыннан сездән күпкә якынрак һәм лаеклыракбыз. Чөнки хак диннең нигезләрендә аерылганыбыз юк һәм аңа да, аның китергәннәренә дә ышанабыз»*, – ди. Шуннан соң әүвәл үзеннән башлап, мөселманнар белән бергә Гашура көнен уразада үткәрә (Бохари, «Саум», 69; «Әнбия», 22; Мөслим, «Сыям», 127/1130).

Башка бер хәдис-шәрифтә, яһүдиләргә охшамас өчен, уразаны мөхәррәмнең тугызында һәм унысында яки унынчы һәм унберенче көннәрендә

тотарга һәм иң азы ике көн тотарга кушыла. Бу хәдис-шәрифтә таләп ителгәнчә, гыйбадәттә дә мөселманнар кяферләрдән аерылып торырга тиеш.

Хәзрәти Гайшә радыйаллаһу ганһә анабыз риваять иткән:

«Корәешләр җаһилият чорында Гашура көнендә ураза тоталар иде. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә, пәйгамбәр булганчыга кадәр, бу уразаны тота иде» (Бохари, «Саум», 69; «Мәнакыйбүл-Әнсар», 26; «Тәфсир», 2/24).

Күпмедер вакыт бу Гашура уразасын тоту гадәте Мәдинәдә дә дәвам итә. Рамазан уразасы фарыз ителгәч, Гашура уразасы кешеләрнең үз теләгенә калдырыла һәм нәфел гыйбадәтләрдән санала башлый. Рамазан уразасына кадәр Гашура уразасын тотуның важиб дәрәҗәсендә булганлыгы турында Бохари һәм Мөслим риваятьләреннән мәгълүм.

Хәзрәти Гайшә радыйаллаһу ганһә риваять кыла:

«Рамазан уразасы фарыз булганчы, Гашура уразасы тотыла иде. Рамазан уразасы фарыз кылынганнан соң, аны теләгән кеше тотты, теләмәгән – тотмады» (Бохари, «Саум», 69; Мөслим, «Сыям», 115).

Хәдис-шәрифтә ул көнне уразада үткәрү турында:

*«Берәр кеше ул көнне иртән ифтар ашаса, көннең калган өлешендә берни дә ашамасын! Берәр кеше уразага ният итсә, уразасын тәмамласын»* (Бохари, «Саум», 69), диелеп, сөннәт дәрәҗәсендәге бу уразаның никадәр фазыйләтле булуы күрсәтелә.

**Нух кавеменең төп һәлак ителү сәбәпләре**

1. Кяфер булалар. Пәйгамбәрләрен, Кыямәт көнен инкяр итәләр.

2. Потларга табыналар һәм ширекне хуплыйлар.

3. Нух галәйһиссәләмне кимсетәләр, буйсынмыйча, аңа золым итәләр.

4. Тәкәббер булалар. Фәкыйрьләргә «оятсызлар» дип дәшәләр. Хикмәт ияләрен дә түбәнсетәләр. Чынлыкта, тәкәбберлекләре аркасында фәкыйрьләр белән бергә утырудан тайчыну – һәлак булган кавемнәрнең төп начар сыйфатларыннан берсе.

5. Хатын-кызларында әдәп, гыйффәт һәм оят булмый.

6. Дөнья ләззәтләренә бик нык биреләләр.

7. Шөкер итмиләр. Югыйсә, Җәнабел-Хак үзе биргән нигъмәтләргә шөкер итәргә һәм яхшылыкның кадерен белергә куша. Бер хәдис-шәрифтә шөкер кылучы һәм сабыр итүче болай тасвирлана:

*«Ике үзенчәлек бар, алар кемдә булса, Аллаһ шуны шөкер итүче һәм сабыр итүче буларак язар. Бу ике үзенчәлек булмаган кешене исә шөкер итүче һәм сабыр итүче буларак язмас.*

*Әгәр берәр кеше дини мәсьәләләрдә үзеннән өстен булучыга карап, аңа иярсә, ә дөньяви мәсьәләләрдә исә үзеннән түбән булучыга карап, Аллаһның биргән нигъмәтләренә мактау әйтсә, шушы кешене Аллаһ шөкер итүче һәм сабыр итүче буларак язар. Дини мәсьәләләрдә үзеннән түбән дәрәҗәдә булучыга карап, дөньяви мәсьәләләрдә исә үзеннән өстен булучыга карап, үзе булдыра алмаганнар өчен борчылган кешене Аллаһ шөкер итүче һәм сабыр итүче буларак язмас»* (Тирмизи, «Кыямәт», 58).

Нух галәйһиссәләм күп шөкер итүче бәндә була. Аллаһ Тәгалә аның бу сыйфатын, бөтен кешелекне илаһи нигъмәтләр каршысында шөкер итүче булырга өндәү өчен, түбәндәгечә искә ала:

إِنَّهُ كَانَ عَبْدًا شَكُورًا

**«Һичшиксез, ул (Нух) бик күп шөкер кылучы бер кол иде»** («әл-Исра», 3).

Әйтик, Нух галәйһиссәләм берәр нәрсә ашаса-эчсә дә, ниндидер кием кисә дә – һәр хәрәкәтендә Җәнабел-Хакка даими мактауларын ирештерә. Киенгәндә дә, ашаганда да, «бисмиллаһ» әйтеп, ашап бетергәч яки киемнәрен салганда, «әлхәмдүлилләһ» әйтә торган була. Шуңа күрә Җәнабел-Хак аны «Габдән шәкура», ягъни «шөкер итүче кол» дип атаган (Ибне Ханбәл, «әз-Зүһд», 50 б.).

Шөкер итү – бәндәнең үзенә бирелгән нигъмәтләргә һәм яхшылыкларга сөенеп, аларны бирүче Раббысына төрле сүзләр һәм мөнәсәбәтләр белән ихлас гыйбадәттә булуы дигән сүз. Ягъни шөкер итү – нигъмәтләрнең хакыйкый иясен белүне аңлата.

Сәрийюс-Сакати: «Берәр кешегә ниндидер нигъмәт бирелеп, аңа шөкер кылмаса, ул нигъмәт кулыннан алыныр!» – дип әйткән.

Моны раслап, Җәнабел-Хак аяти кәримәдә әйтә:

لَئِنْ شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ وَلَئِنْ كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ

**«Раббыгыз: “Әгәр шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә** (нигъмәтемне) **арттырачакмын. Әгәр рәхмәтле булмасагыз, һичшиксез, газабым бик каты”, – дип игълан итте»** («Ибраһим», 7).

**Нух галәйһиссәләмнең кайбер сыйфатлары**

1. Хезмәт кешесе булуы.

2. Диңгезгә чыгуы һәм диңгездән куллануы.

3. Күп шөкер итүче һәм сабыр итүче кол булуы.

4. Күп тәүбә кылуы.

Нух галәйһиссәләмнең пәйгамбәрлеге 950 ел дәвам итә һәм Аллаһның бу бөек пәйгамбәре, озын гомер яшәгәннән соң, һәр фани мәхлук кебек, җанын Раббысына тәслим кыла. Вафаты алдыннан янында булган балаларына исә Бөек Аллаһка гыйбадәт кылуны дәвам итәргә кушып калдыра. Соңыннан угылы Сәмга:

«Балам, калебеңдә тузан бөртеге кадәр генә ширек булса да, кабергә кермә! Чөнки Аллаһ Тәгаләнең хозурына мөшрик буларак килгән кеше өчен һичбер гафу юк.

Балам, калебеңдә тузан бөртеге кадәр генә тәкәбберлек булган хәлдә кабергә кермә! Чөнки горурлык – Бөек Аллаһның зиннәте. Бу хакта бәхәс итүчегә, ягъни Җәнабел-Хакка хас бер сыйфатны үзенә лаек күргән кешегә Аллаһ Тәгалә газап бирер.

Балам, калебеңдә тузан бөртеге кадәр генә өметсезлек (рәхмәттән өмет өзелү) булган хәлдә кабергә кермә! Чөнки хак юлдан тайпылганнардан кала, башка кеше Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзмәс.

Балам, сиңа тәүхид кәлимәсен – « لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ » сүзләрен әмер итәм. Чөнки җиде кат күкләр белән җиде кат җир үлчәүнең бер тәлинкәсенә, тәүхид кәлимәсе икенчесе тәлинкәсенә куелса, бу сүзләр алардан да авыррак булыр» (Ибне Ханбәл, «Муснәд», II, 170; «әз-Зүһд», 51 б.; Хәйсәми, IV, 219).

Риваятьләрдә әйтелгәнчә, үлем якынайгач, Хәзрәти Нух галәйһиссәләмнән: «Әй Әбүл-Бәшәр, әй озын гомерле Пәйгамбәр! Дөньяны ошаттыңмы?» – диеп сорала.

Нух галәйһиссәләм: «Аны ике ишекле бер өйгә охшаттым. Бер ишегеннән кердем, икенчесеннән чыктым», – дип җавап бирә (Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 73).

Хәзрәти Нух галәйһиссәләм үзенә камыштан бер алачык ясаган була. Аңа: «Үзеңә моннан ныклырак берәр өй төзесәң иде», – дигәч: «Үләсе кеше өчен монысы да бик күп әле!» – дип җавап кайтарган (Әбу Нугайм, «Хилья», VIII, 145).

Мөшрикләрнең, кяферләрнең, явызларның төрле җәберләре астында 950 елга якын вакыт дәвамында халкына түзеп яшәве белән үзеннән соң килгән пәйгамбәрләр һәм өммәтләргә үрнәк күрсәтеп, илаһи хөрмәткә лаек булган Нух галәйһиссәләмнән безгә калган иң күркәм мирас – «сабырлык» булды.

Галәйһиссәләм...

# САБЫРЛЫК

Сабырлык – «түземлек, чыдамлык күрсәтү, чиктән ашудан саклану, авыртуга түзү; авырлыкларга, кайгы-борчуларга тарыганда, салкын канлылык саклап, аларга каршы тору; акыл һәм дин күрсәткән юлда үҗәтлек» кебек мәгънәләрне белдерә.

Бөтен күркәм әхлак сыйфатларын колачлаганга күрә, сабырлык динебездә бик хөрмәтле урын били. Сабырлык Аллаһның ризалыгына ирешү өчен бер сәбәп тәшкил иткән мөбарәк әхлакый сыйфат булып тора. Дин һәм әхлак күзлегеннән исә сабырлык – күңелгә хуш килмәгән һәм авырту-газаплар китергән хәлләргә тарыганда, бер чиктән икенче чиккә ташланмыйча, тынычлык саклау, үзеңне Хак Тәгаләгә багышлау дигән сүз.

Бу мәсьәләгә карата Имам Нәвәви болай ди:

«Сабырлык – нәфесне Аллаһ кушкан нәрсәләрне үтәүгә мәҗбүр итү ул. Бу исә гыйбадәтләргә бәйле мәшәкатьләргә, төрле бәла-казаларга, гөнаһ булмаган зарарлы нәрсәләргә карата түземлек күрсәтү аша чынга аша».

Сабыр ителергә тиешле вакыйгалар белән очрашканда, без рухи сыйфатлардан саналган кече күңеллелек, йомшаклык, хаталарны кичерә белү, аз белән канәгатьләнү, шәфкать, мәрхәмәт, нәзакәтлек һәм толерантлык кебек әхлакый сыйфатларыбызны эшкә җигүебез таләп ителә.

Сабырлык күркәм әхлакның төп үзәген тәшкил итә. Иманның яртысы, күңел тынычлыгы һәм бәхет ачкычы ул. Җәннәт нигъмәтләренә ирештерә торган олуг фазыйләт. Төрледән-төрле хәерле нәрсәләр һәм югары казанышлар «сабырлык» белән бәйле булганга күрә, беренче чиратта, ныклык іяләре булган пәйгамбәрләр, гомумән, барлык нәбиләр, әүлиялар һәм галимнәр сабырлыкны бер гадәткә әйләндергәннәр.

Коръәни-Кәримдә сабырлык турында җитмештән артык урында искә алына. Төрле аятьләрдә Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә һәм Аның шәхесендә бөтен өммәткә сабыр булырга киңәш ителә. Бу аятьләрдән кайберләре:

وَاصْبِرْ وَمَا صَبْرُكَ إِلَّا بِاللَّهِ وَلَا تَحْزَنْ عَلَيْهِمْ وَلَا تَكُ فِي ضَيْقٍ مِمَّا يَمْكُرُونَ

**«Сабыр бул, чөнки синең сабырың Аллаһ** (ярдәме) **белән генә. Алар өчен** (иманга килмиләр, дип) **көенмә, корган хәйләләре сәбәпле тарлык кичермә!»** («ән-Нәхел», 127).

وَاصْبِرْ لِحُكْمِ رَبِّكَ فَإِنَّكَ بِأَعْيُنِنَا وَسَبِّحْ بِحَمْدِ رَبِّكَ حِينَ تَقُومُ

**«Син Раббыңның хөкеменә сабыр ит! Һичшиксез, син – Безнең саклавыбызда. Аякта торган чагыңда Раббыңны мактап тәсбих ит!»** («әт-Тур», 48).

وَاصْبِرْ حَتَّى يَحْكُمَ اللّٰهُ

**«…Аллаһ хөкемен биргәнчегә кадәр сабыр ит!..»** («Йунус», 109).

وَاصْبِرْ نَفْسَكَ مَعَ الَّذِينَ يَدْعُونَ رَبَّهُمْ بِالْغَدَاةِ وَالْعَشِيِّ يُرِيدُونَ وَجْهَهُ

**«Иртә-кич Раббыларына Аның ризалыгын сорап дога кылучылар белән үзеңне сабыр тот!..»** («әл-Кәһф», 28).

Пәйгамбәрләрнең тормышы тәүхид дин өчен көрәш барышындагы кыенлыклар каршында күрсәтелгән дастаннарга тиң сабырлык үрнәкләре белән тулы. Хәзрәти Нух галәйһиссәләм кыйналу һәм төрлечә кимсетелү кебек газапларга 950 ел сабыр итә. Хәзрәти Муса галәйһиссәләм Исраил улларына:

اسْتَعِينُوا بِاللّٰهِ وَاصْبِرُوا

**«…Аллаһтан ярдәм сорагыз һәм сабыр булыгыз!..»** – дип киңәш бирә («әл-Әгъраф», 128). Хәзрәти Әйюб галәйһиссәләм башына төшкән төрле бәла-казаларга һәм кыенлыкларга сабыр итә һәм:

إِنَّا وَجَدْنَاهُ صَابِرًا نِعْمَ الْعَبْدُ إِنَّهُ أَوَّابٌ

**«…Һичшиксез, Без аны сабыр итүче буларак таптык. Нинди күркәм бер кол иде! Һичшиксез, ул күп тәүбә кылучы иде!»** – дип искә алырлык илаһи хөрмәткә лаек була («Сад», 44). Аяти кәримәдә әйтелгәнчә, Хәзрәти Локман галәйһиссәләм улына:

يَا بُنَيَّ أَقِمِ الصَّلٰوةَ وَأْمُرْ بِالْمَعْرُوفِ وَانْهَ عَنِ الْمُنْكَرِ وَاصْبِرْ عَلَى مَا أَصَابَكَ إِنَّ ذٰلِكَ مِنْ عَزْمِ الْأُمُورِ

**«И, улым! Намаз укы, яхшы дип беленгән нәрсәне әмер ит, яхшы дип танылмаган нәрсәдән тый һәм сиңа килгән нәрсәләргә сабыр ит. Һичшиксез, бу – билгеләнгән эшләрдән!»** – дип үгет-нәсыйхәт биргән («Локман», 17).

Хәзрәти Пәйгамбәр галәйһис-саләтү вәс-сәләәм исә, аерым алганда, Мәккә һәм Таиф халкының җәбер-золымына каршы бик зур сабырлык күрсәтә, күпмедер вакыттан соң, бу кешеләр иман нуры белән хөрмәтләнә.

Пәйгамбәрләр һәм әүлиялар, сабырлык саклап, Аллаһның ярдәменә ирешәләр. Шул сәбәпле, алар безнең өчен үрнәк шәхесләр булырга тиеш. Сабырлыкның дөньялыктагы ягы бик авыр, ачы, ахирәттәге ягы бик татлы. Сабырлыкның ачысын татыганнар мәңгелек иле булган җәннәткә һәм Аллаһның ризалыгына ирешер.

Нәфесебез никадәр генә теләсә дә, хәрәм нәрсәләргә күңел бирмәскә; ничек кенә авыр булса да, сабыр итеп, түземлек күрсәтергә тиешбез. Аллаһ кушканнарны, никадәр читен булса да, сабырлык белән үтәргә бурычлыбыз!

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сабырлыкның төрләре һәм фазыйләтләре турында сүз барган хәдис-шәрифендә болай ди:

*«Сабырлык өч төрле була: бәла-казаларга карата сабырлык, гыйбадәтләрне сабырлык белән кылу һәм гөнаһ эшләрне кылмауда сабырлык итү.*

*Кем дә кем кыяматтә терелтелгәнчегә кадәр бәла-казаларга карата күркәм сабырлык күрсәтсә, Аллаһ аңа өч йөз дәрәҗә әҗер яза. Һәр ике дәрәҗә арасында күк белән җир арасы кадәр ераклык бар. Кем дә кем гыйбадәттә сабыр итсә, Аллаһ аңа алты йөз дәрәҗә әҗер яза. Һәр ике дәрәҗә арасында җир белән җиде кат җир асты арасы кадәр ераклык бар. Кем дә кем гөнаһларга каршы сабыр итсә, Аллаһ тугыз йөз дәрәҗә әҗер яза. Ике дәрәҗә арасында җир белән гареш арасы кадәр ераклык бар»* (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 42; Дәйләми, II, 416).

Нинди генә очрак булмасын, Аллаһ кушканнар һәм тыйганнардагы нигъмәт, хикмәт һәм илаһи әҗер турында уйлау сабыр итүне җиңеләйтә. Кайчак өстебезгә төшкән табигый авырлыкларга түзүдән башка чарабыз юк. Һәр чарасызлыкның бердәнбер чарасы – Аллаһ. Зарланулар, акыра-бакыра елау-сыктаулар – үз-үзебезне бетерү генә ул. Шуңа күрә дә, башыбызга төшкән бәла-казларга сабыр итеп, Җәнабел-Хакка сыену, һәрнәрсәнең Аңардан килгәнлеген белү һәм бер сынау икәнлеген аңлап, әҗер-савабын уйлау иң акыллы гамәл булып тора.

Кешенең бер сынау дөньясында һәр теләгән нәрсәсенең чынга ашуы мөмкин түгел. Үзебез ирешә алмаган нәрсәләргә карата «булмавы безнең өчен хәерледер» яки «булганнарында хәер бар», дип әйтү Аллаһ каршында коллыгыбызны раслау өчен иң ярашлы һәм безне рухи дәрәҗәләргә күтәрә торган күркәм гамәл санала.

Сабырлык ул – бәндәнең мәҗбүрилек белән түгел, ә күңеленә хуш рәвештә үз-үзен Раббысына багышлавы. Әле көч-куәте булган хәлдә, сабыр итеп, үч алмау да олуг фазыйләт дип бәяләнә. Сабырлык иң әүвәл бәла-казага тарыган мизгелдә күрсәтелергә тиеш. Вакыты узган сабырлык өчен әллә ни әҗер-савап язылмас. Шунлыктан да баласын яки якын кешесен югалткан затның тәүге мизгелдәге сабырлыгы, үзен Аллаһка багышлавы бик мөһим!

Әнәс ибне Малик радыйаллаһу ганһедән риваять кылынганча, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм бервакыт баласының кабере янында кычкырып елаган бер хатын яныннан узып бара. Аңа:

*«Аллаһтан курык һәм сабыр ит!»* – дип боера.

Теге хатын: «Бар, кит моннан! Минем башыма төшкән кайгы синекенә килгәне юк!» – ди.

Бу хатын Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне танымый. Аңа соңыннан ул кешенең Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм булганын әйтәләр. Бу хакта ишетүгә, хатын Пәйгамбәребезнең йортына йөгерә. Анда үзенә комачауларлык һичкем булмагач, туп-туры Рәсүлүллаһ янына керә һәм (гафу сорап): «Йә, Рәсүлүллаһ, Сезне танымадым», – ди. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

إِنَّمَا الصَّبْرُ عِنْدَ الصَّدْمَةِ الْأُولَى

*«Чын сабырлык кайгы килүнең тәүге мизгелендә күрсәтелә!»* – дип белдерә (Бохари, «Җәнаиз», 32).

Җәнабел-Хакның күркәм исемнәренең берсе дә – «әс-Сабур», ягъни Җәнабел-Хак колларына күпмедер срок бирә һәм шул вакыт дәвамында хәтта Аны инкяр итүчеләрне дә ризыкландырып, сабыр итә. Әгәр Раббыбыз дөньялыкта гөнаһлылардан шундук үч алырга теләсә, бу галәм нинди хәлгә төшәр иде?.. Уйлап карагыз әле!..

Аяти кәримәдә әйтелә:

وَلَوْ يُؤَاخِذُ اللّٰهُ النَّاسَ بِمَا كَسَبُوا مَا تَرَكَ عَلَى ظَهْرِهَا مِنْ دَابَّةٍ وَلَكِنْ يُؤَخِّرُهُمْ إِلَى أَجَلٍ مُسَمًّى

**«Әгәр Аллаһ кешеләрне, кылган гөнаһлары сәбәпле, тотып алган булса, аның өстендә кыймылдаган бернинди җанны да калдырмас иде, ләкин Ул аларны билгеләнгән бер вакытка кадәр кичектерә...»** («Фатыйр», 45).

«Сабур» исем-шәрифе (сыйфаты), әхлакка кереп урнашып һәм аны үзгәртеп, иң күркәм шәкелдә пәйгамбәрләр һәм әүлияларда чагылыш таба. Муллык һәм фәкыйрьлек чорларында аеруча мөһим булган сабырлык алардан безгә күчкән иң матур әдәп-әхлак үрнәкләренең берсен тәшкил итә.

Муллыкта сабырлык чиктән тыш горурлык һәм тәкәбберлеккә батмау, үч алудан тыелу, шәһвәткә бирешмәү, саранланмау, исраф кылмау, фәкыйрьләрне кимсетмәү, эшләнгән яхшылыкка җавап сорамау кебек сыйфатларга ия булудан гыйбарәт, чөнки нәфес кешене гел начар сыйфатларга, эш-гамәлләргә этәрә. Бу очракта сабыр итеп, киләчәктә ачы язмышка тарымау зарур.

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләмнең тормышы муллыктагы сабырлыкка бик күркәм мисал булып тора. Ул дөньялыктагы бернәрсәгә дә мөкиббән китми, киресенчә, дөньядагы һәрнәрсәне Раббысының бер әманәте дип кабул итә. Җәнабел-Хак аңа бу дөньяда бик күп мөмкинлекләр биргәндә дә, сабырлык күрсәтеп, нәфесе теләгән һәрнәрсәдән тыела һәм шул рәвешле «Хәлил» кушаматына лаек була.

Сөләйман галәйһиссәләм дә, бу дөньяда Җәнабел-Хак биргән солтанлыкка күңел бирмичә, мөлкәткә хирыслыкның йөрәккә үтеп керүенә ирек бирми. Ул фәкыйрьләр янына бик еш килә, алар белән бергә утырудан канәгатьлек ала һәм: «Мескен мескеннәр белән уртак тел таба!» – дип әйтә. Шул рәвешле

дөньяда солтан булган хәлдә иң күркәм дәрәҗәдәге кече күңеллелек үрнәге күрсәтә (Карагыз: Ибне Әби әд-Дүнья, «әт-Тәваду», № 103).

Кыенлыкта, кысанлыкта сабырлык исә зарлану, хөсетлек, сер тотмау, үпкә, үч-нәфрәт, гаилә әгъзалары һәм якыннар белән матур мөнәсәбәтләр кормау кебек начар сыйфатлардан саклану дигән сүз. Мондый хәлләрдә сабырлык күрсәтеп, начар эш-гамәлләрдән һәм уй-ниятләрдән тыелырга тырышу таләп ителә. Шуңа күрә пәйгамбәрләр һәм әүлияларның муллыкта һәм ярлылыктагы хәл-әхвәлләреннән гыйбрәт алу һәм аларга охшарга омтылу зарур.

Пәйгамбәребез мөэминнәрнең берәр бәла-каза һәм кыенлык вакытында өметсезлеккә бирелмичә, Аллаһ Тәгаләгә тәвәккәл кылырга һәм Аңа ялварырга тиешлекләрен түбәндәгечә киңәш итә:

*«Үзенә бер бәла-каза килгән мөселман, Аллаһ кушканча:*

إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ. اَللَّهُمَّ أْجُرْنِى فِى مُصِيبَتِى وَأَخْلِفْ لِى خَيْرًا مِنْهَا

*«Без – Аллаһныкы һәм Аңа гына кайтачакбыз. "Аллаһым! Миңа бу бәла сәбәпле әҗер бир һәм миңа моннан да хәерлерәкне насыйп ит!" – дисә, Аллаһ ул бәла-казаны бетерер һәм, һичшиксез, хәерлерәкне бирер»* (Мөслим, «Җенаиз», 3).

Муллыкта һәм кыенлыкта йөрәгебезне афәттән коткару һәм Аллаһ ризалыгына ирешү өчен, без сабыр итәргә мәҗбүр һәм тиеш! Хәзрәти Әйюб галәйһиссәләмнең түбәндә бәян ителгән бер тормыш мизгеле кыен чактагы сабырлыкка нинди күркәм үрнәк булып тора:

Җәмәгате Рәхимә Хатун аңа: «Син пәйгамбәр бит, догаң кабул була. Бик каты авырыйсың! Дога укы да Аллаһтан шифасын ал!» – ди.

Хәзрәти Әйюб галәйһиссәләм исә: «Аллаһ миңа сиксән ел саулык бирде. Авыруым исә сиксән ел булмады. Әле берничә ел гына чирлим. Җәнабел-Хактан саулык сорарга оялам!» – ди.

Ахыр чиктә әлеге хөрмәтле пәйгамбәр дастаннарга керерлек сабырлыгы нәтиҗәсендә элекке саулыгына, яшьлегенә һәм мул тормышына кире кайтарыла.

Муллыкта яшәп, кулында һәр мөмкинлек була торып та, сабыр итүчеләрне «агния-и шакирин» (рәхмәтле, шөкер итүче байлар) дип атыйлар. Кыенлыкта, ярлылыкта күңелләрен Раббыларына биреп, һич зарланмыйча, шөкер итеп яшәүчеләрне «фукара-и сабирин» (фәкыйрьлектә сабыр итүчеләр) диләр. Агния-и шакирин һәм фукара-и сабирин булганнарга хисапсыз әҗер-савап турында сөенечле хәбәрләр бар.

Уразалы беркөнне Габдеррахман ибне Гауф радыйаллаһу ганһе өчен бик мул ифтар табыны әзерләнә. Ләкин ул, ризыкларга күз ташлап, болай ди: «Мусгаб ибне Гомәйр Өхед сугышында шәһид китте. Ул миннән фазыйләтлерәк иде. Әмма кәфен өчен җиләненнән кала һичнәрсәсе юк иде. Аның белән

башын капласак – аяклары, аякларын төрсәк, башы ачык кала иде. Соңыннан дөньялыкта безгә һәрнәрсә бирелде. Дөреслектә, яхшылыкларыбыз өчен әҗернең дөньялыкта бирелүеннән куркам».

Соңыннан Габдеррахман ибне Гауф радыйаллаһу ганһе елый башлый һәм табыннан чыгып китә (Бохари, «Җенаиз», 27).

Әсхәбе кирамның иң хөрмәтлеләреннән Әбү Зәрр радыйаллаһу ганһе бик ярлы була. Шуңа карамастан, Аллаһ юлында мал сарыф итүдән баш тартмый һәм гомерен шөкер кылып кичерә, чөнки Пәйгамбәребез аңа:

*«Йә, Әбү Зәрр! Шулпаңа тагын бераз су өстәп, күршеңне дә кайгырт»,* – дип әйткән була (Мөслим, «Бирр», 142).

Күңелләренә Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мәхәббәтен салган, бөек сабырлык үрнәге күрсәткән берсе бай, икенчесе ярлы ике сәхабә!.. Берсе мул тормышта, берсе фәкыйрьлектә булса да, аларның бер үк төрле рухи халәт кичереп, Аллаһ ризалыгына ирешү һәм эчкерсез иман белән яшәү өчен кылганнары сабырлыкның нинди камил чагылышы булып тора. Без дә бу хис-тойгыларга ия булыйк, дисәк, зикергә, иманлы әңгәмәләргә, Аллаһ юлында сарыф ителәчәк хәер-сәдакалар бирүгә һәм ихлас күңелдән укыла торган догаларга мохтаҗбыз!..

Җәнабел-Хак:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اصْبِرُوا وَصَابِرُوا

**«И, иман китерүчеләр! Сабыр итегез, сабырлыкта ярышыгыз** (дошманнарыгызны узыгыз)**!..»** – дип боера («Әли Гыймран», 200).

Башка аятьләрдә Җәнабел-Хак болай ди:

وَالْعَصْرِ. إِنَّ الْإِنْسَانَ لَفِي خُسْرٍ. إِلَّا الَّذِينَ آمَنُوا
وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ وَتَوَاصَوْا بِالْحَقِّ وَتَوَاصَوْا بِالصَّبْرِ

**«Икенде намазы вакыты белән ант итәмен. Һичшиксез, кешеләр – зарарда. Бары иман китергән, изге гамәлләр кылган һәм бер-берләрен хакка өндәгән һәм бер-берләрен сабырлыкка өндәгән кешеләр булмасалар гына»** («әл-Гаср», 1–3).

Ләкин башкаларны хак нәрсәгә һәм сабырлыкка чакыру өчен, боларны беренче чиратта шәхси тормышта куллану, шулар белән гомер кичерү зарур.

Җәнабел-Хак барыбызга да сабырлык насыйп итсен! Барлык пәйгамбәрләр һәм әүлияларның сабырлыгыннан, киң күңеллелегеннән безгә дә өлеш чыгарып, тәкатебез җитмәслек сынаулардан сакласын!..

Амин!..

***Хәзрәти Нух галәйһиссәләм***





ХӘЗРӘТИ

# Һуд

*галәйһиссәләм*

*Давыллар белән асты-өскә китерелгән Гад кавеме пәйгамбәре*

# ХӘЗРӘТИ ҺУД

***галәйһиссәләм***

Һуд галәйһиссәләм Самның оныкларыннан була. Гад кавеменә пәйгамбәр итеп җибәрелә.

«Һәвадәт» кәлимәсе белән тамырдаш булып, «һуд» сүзе «йомшаклык», «тынычлык», «солых һәм иминлеккә сәбәп булуы өмет ителгән» дигән мәгънәләр белдерә. Һуд галәйһиссәләмнең башка исеме – Абир, кушаматы – Нәбиуллаһ.

Хәзрәти Һуд галәйһиссәләм Ахкаф дип аталган төбәктә туып үсә. Гад кавемендә абруйлы нәсел вәкиле була. Пәйгамбәрлеккә кадәр сәүдә белән шөгыльләнә. Уртача буйлы, карасу тәнле, куе чәчле, матур йөз-кыяфәтле ир-ат. Адәм галәйһиссәләмгә охшаган була.[60] Аллаһтан куркып, тәкъва тормыш алып бара, гыйбадәткә бирелә. Юмартлыгы һәм шәфкатьлелеге билгеле: ятимнәргә мул сәдака өләшә.

**Гад кавеме**

Гад кавеме турында Коръәни-Кәримнең «Әгъраф», «Һуд», «Мүэминүн», «Шугара», «Фуссыйләт», «Әхкаф», «Зарият», «Камәр», «Хәкка» һәм «Фәҗер» сүрәләрендә искә алына. Гад кавеме егерме өч кабиләдән оешкан гарәп халкы була. Кавемгә исеме бирелгән Гад – Хәзрәти Нухның бер оныгы. Яшәгән чоры Хәзрәти Нухтан сигез йөз соңрак дип фаразлана.

Һәлакәтләре бөтен кешелек өчен гыйбрәткә әйләнгән Гад кавеме Йәмән, Аден һәм Оман арасындагы Ахкаф дигән җирлектә яши. Гад кавеме Гарәбстан ярымутравына килеп урнашкан, «гарәбүл-гарибә» дип аталган тәүге кавемнәрдән санала. Уңдырышлы туфракларга ия бу кавем көтүлекләргә, суга һәм төрле нигъмәтләргә бай, бакчалы төбәктә гомер кичерә. Җирләрендә гөрләп елга-инешләре агып тора, бакчалары шау чәчәк ата, көтү-көтү маллары йөри, җир астында, мөгаен, зур-зур су запаслары булгандыр.[61] Ахкаф төбәге хәтта «Ирәм» атамасы белән дә таныла. Атаклы «Ирәм баглары» (җәннәт бакчалары) сүзтезмәсе дә шуннан барлыкка килә. Бу кавем кешеләре зур гәүдәле, озын буйлы, көчле, озын гомерле була. Гад кавеме кыя-ташларны кыеп-кисеп өйләр сала, матур биналар төзи. Аларның эчендә төрле бакчалар һәм матур бассейннар корыла. Һәр тараф күзләрне камаштырырлык итеп матурлана.

60. Карагыз: Хаким, «әл-Мүстәдрәк», II, 614–616.
61. Карагыз: «әш-Шугара», 129, 133, 134.

Гад халкы Нух туфаныннан соң потпәрәстлеккә беренче булып кире кайта. Бу кавем, вакытлар узу белән, дөнья нигъмәтләренә күмелүе аркасында, Аллаһны онытa, төрле фетнәләр һәм бозыклыклар йогынтысында диннән ерагая. Нух туфанының куркынычын һәм асыл хикмәтен уйламыйча, дөнья ләззәтенә биреләләр. Алар Аллаһтан килгән нигъмәтләрнең күплеген күреп алдана. Бу халыкта тәкәбберлек көчәя, үз-үзләрен мактый, кәпрәя башлыйлыр. Аллаһ Тәгалә алар хакында болай ди:

فَأَمَّا عَادٌ فَاسْتَكْبَرُوا فِي الْأَرْضِ بِغَيْرِ الْحَقِّ وَقَالُوا مَنْ أَشَدُّ مِنَّا قُوَّةً أَوَلَمْ يَرَوْا أَنَّ اللَّهَ الَّذِي خَلَقَهُمْ هُوَ أَشَدُّ مِنْهُمْ قُوَّةً وَكَانُوا بِآيَاتِنَا يَجْحَدُونَ

**«Гадкә килгәндә, алар җирдә хаксызга тәкәбберләнделәр һәм: “Куәт ягыннан кем бездән көчлерәк?” – диделәр. Алар үзләрен яралткан Аллаһның куәт ягыннан алардан көчлерәк булганын күрмәделәрме? Алар Безнең аятьләребезне инкяр иттеләр»** («Фуссыйләт», 15).

Алар илаһи туры юлдан шулкадәр читкә тайпыла ки, Самәд, Самуд, Сада һәм Хәба исемле потлар ясап, шуларга табына башлыйлар. Залим, мәрхәмәтсез бәндәләргә әйләнәләр. Көчсезләрне, ятимнәрне җәберлиләр, мескен, зәгыйфь бәндәләрне биек биналарның өстенә алып менеп, шуннан аска ыргыталар. Аннары шуларның изелгән, таралган гәүдәләрен карап, шуннан ләззәт алалар, ягъни йөрәкләре шулкадәр ката, шулкадәр кырыслана. Золым, явызлык күз алдына да китерә алмаслык дәрәҗәгә җитә. Гад халкы, зәгыйфь кабиләләргә яу чабып, аларның малларын талый. Ләззәтле, бай, шапырыну өчен алып барыла торган тормышта бик алга китәләр. Әнә шуңа күрә Һуд галәйһиссәләмнең Гад кавеме Нух туфаныннан соң һәлак ителгән беренче кавем була да. Ләкин Хәзрәти Һуд галәйһиссәләм бу кавем белән бары тик нәсел-нәсәп ягыннан гына бәйләнгән. Ул бөтенләй башка төрле яшәү рәвеше алып бара. Ул пакь күңелле, абруйлы гаилә баласы була.

Гад кавеме азгынлыкта, Аллаһ Тәгаләгә каршы килүдә чиктән ашып, бозыклыклары көннән-көн арткач, Җәнабел-Хак Хәзрәти Һуд галәйһиссәләмгә мондый вәхи иңдерә:

«Әй Һуд! Кавемнән сине сайлап алдым. Алар янына бар, курыкма! Сиңа ышансыннар өчен, Мин аларга могҗизалар күрсәтәчәкмен...»

Вәхине алгач, Һуд галәйһиссәләм кавеме җыелган урынга юнәлә. Бу вакытта Халҗан исемле башлыклары алтын тәхеттә утыра. Хәзрәти Һуд хөр тавыш белән сүз башлый:

«Әй, кавемем! Гыйбадәт кылырга лаеклы зат бары Аллаһ кына. Аңа тиңдәшләр куймагыз! Уйлап карагыз әле: Нух кавеме әнә шуңа һәлак ителде!»

Аяти кәримәдә Һуд галәйһиссәләмнең иманга чакыруы түбәндәгечә искә алына:

وَيَا قَوْمِ اسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ ثُمَّ تُوبُوا إِلَيْهِ يُرْسِلِ السَّمَاءَ عَلَيْكُمْ
مِدْرَارًا وَيَزِدْكُمْ قُوَّةً إِلَى قُوَّتِكُمْ وَلَا تَتَوَلَّوْا مُجْرِمِينَ

**«И, кавемем! Раббыгыздан мәгъфирәт сорагыз, шуннан Аңа тәүбә кылыгыз. Ул мул итеп күкне яудырыр һәм куәтегезгә куәт кушып, сезне арттырыр. Әмма сез, гөнаһлылар буларак,** (Аллаһтан) **йөз чөермәгез!»** («Һуд», 52).

Халҗан кызып китә:

«Әй Һуд! Башыңа бәла булсын! Без шундый көчле һәм күп санлы булган хәлдә, син безне җиңәм, дип уйлыйсыңмы? Әллә үзеңнең гап-гади бер кеше икәнлегеңне белмисеңме?! Һәр көн бездә меңәр бала туганын да белмисеңме әллә?» – ди.

Кыскасы, Халҗан һәм Гад халкы, балалары һәм байлыклары белән горурланып, Һуд галәйһиссәләмгә кимсетеп карыйлар һәм иманга килмиләр. Бу вакыйга аяти кәримәләрдә болай сурәтләнә:

عَادٍ أَخَاهُمْوَإِلَى عَادٍ أَخَاهُمْ هُودًا قَالَ يَا قَوْمِ اعْبُدُواْ اللّهَ مَا لَكُم مِّنْ إِلَـهٍ غَيْرُهُ أَفَلاَ
تَتَّقُونَ. قَالَ الْمَلأُ الَّذِينَ كَفَرُواْ مِن قَوْمِهِ إِنَّا لَنَرَاكَ فِي سَفَاهَةٍ وِإِنَّا لَنَظُنُّكَ مِنَ الْكَاذِبِينَ
لَنَظُنُّكَ مِنَ الْكَاذِبِينَقَالَ يَا قَوْمِ لَيْسَ بِي سَفَاهَةٌ وَلَكِنِّي رَسُولٌ مِّن رَّبِّ الْعَالَمِينَ

**«Гад кавеменә исә кардәшләре Һудны** (җибәрдек). **Ул әйтте: “И, кавемем! Аллаһка гыйбадәт кылыгыз, сезнең Аннан башка һичбер илаһыгыз юк. Һаман курыкмыйсызмы әллә?” Кавеме эченнән кяфер булган олуг кешеләре әйтте: “Һичшиксез, без синең бер акылсызлык эчендә булганыңны күрәбез һәм без сине ялганчылардан саныйбыз”. Ул әйтте: “И, кавемем! Миндә акылсызлык юк, ләкин мин – галәмнәрнең Раббысыннан бер илчемен!”»** («әл-Әгъраф», 65–67).

Кавеменең Һуд галәйһиссәләмгә каршы килүе һәм аны кире кагуы турында «Һуд» сүрәсендә белдерелә:

قَالُوا يَا هُودُ مَا جِئْتَنَا بِبَيِّنَةٍ وَمَا نَحْنُ بِتَارِكِي آلِهَتِنَا عَنْ قَوْلِكَ وَمَا نَحْنُ لَكَ بِمُؤْمِنِينَ. إِنْ
نَقُولُ إِلَّا اعْتَرَاكَ بَعْضُ آلِهَتِنَا بِسُوءٍ قَالَ إِنِّي أُشْهِدُ اللَّهَ وَاشْهَدُوا أَنِّي بَرِيءٌ مِمَّا تُشْرِكُونَ

**«Әйттеләр: “И, Һуд! Син безгә бернинди ачык дәлил дә китермәдең. Без синең сүзең сәбәпле генә илаһларыбызны беркайчан да калдырмая-**

**чакбыз. Без сиңа иман китермәячәкбез. Без фәкать: “Илаһларыбызның берсе сиңа бер яманлык җибәргән”, – дип кенә әйтә алабыз»** («Һуд», 53–54).

Хәзрәти Һуд галәйһиссәләмгә каршы килгәндә Гад кавеме әйткән сүзләр, сылтаулар башка пәйгамбәрләргә каршы әйтелгән дәлилләрдән аерылмый. Хәтта хәзерге көндәге кяферләрнең дәлил дип санаган нәрсәләре дә нәкъ шундый ук. Бу сылтаулар, дәлилләр, һәр чордыгача, күп очракта кавемнең иң алдынгы кешеләре тарафыннан әйтелә. Мондый үҗәтлек һәм кире кагуларның төп сәбәбе исә бу кешеләрнең дөньялыктагы мәнфәгатьләренә куркыныч янау белән бәйле. Һуд галәйһиссәләм дәгъватын кире кагу өчен, аның кавеме тарафыннан әйтелгәннәрне кыскача берничә өлешкә аерып карарга мөмкин:

1. Хәзрәти Һудны акылдан язуда, адашуда гаеплиләр һәм бу хәл аяти кәримәләрдә дә билгеләп үтелә:

إِنَّا لَنَرَاكَ فِي ضَلَالٍ مُبِينٍ

**«…Без сине ап-ачык бер адашу эчендә күрәбез»** («әл-Әгъраф», 60);

إِنَّا لَنَرَاكَ فِي سَفَاهَةٍ وِإِنَّا لَنَظُنُّكَ مِنَ الْكَاذِبِينَ

**«…Һичшиксез, без синең бер акылсызлык эчендә булганыңны күрәбез һәм без сине ялганчылардан саныйбыз»** («әл-Әгъраф», 66).

2. Ата-бабалары дине иң дөрес юл, дип уйлап, шуңа сукырларча бәйле булып калалар. Аяти кәримәдә аларның мондый мөнәсәбәте:

قَالُواْ أَجِئْتَنَا لِنَعْبُدَ اللّهَ وَحْدَهُ وَنَذَرَ مَا كَانَ يَعْبُدُ آبَاؤُنَا فَأْتِنَا بِمَا تَعِدُنَا إِن كُنتَ مِنَ الصَّادِقِينَ

**«Әйттеләр: “Син без аталарыбыз табынганнарны ташлыйк һәм бер генә булган Аллаһка гыйбадәт кылыйк, дип килдеңме әллә?”»** – дип искә алына («әл-Әгъраф», 70).

3. Үзләренең көчле икәнлекләрен тәкрарлап, алар Хәзрәти Һуд тарафыннан үзләренә бернинди дә зарар китерелә алмаячагын белдерәләр. Аяти кәримәдә аларның күкрәк кагуы әйтелә:

… فَأَمَّا عَادٌ فَاسْتَكْبَرُوا فِي الْأَرْضِ بِغَيْرِ الْحَقِّ وَقَالُوا مَنْ أَشَدُّ مِنَّا قُوَّةً

**«Гадкә килгәндә, алар җирдә хаксызга тәкәбберләнделәр һәм “куәт ягыннан кем бездән көчлерәк?” диделәр…»** («Фуссыйләт», 15).

4. Ахирәтне кире кагып, тормышның бары дөньяда яшәүдән генә гыйбарәт икәнен сөйлиләр. Аларның бу ваемсыз һәм надан фикерләве турында Раббыбыз аяти кәримәдә хәбәр итә:

إِنْ هِيَ إِلَّا حَيَاتُنَا الدُّنْيَا نَمُوتُ وَنَحْيَا وَمَا نَحْنُ بِمَبْعُوثِينَ

**«Ул – безнең дөнья тормышыбыз. Без үләбез һәм яшибез. Һәм без** (үлгәннән соң) **терелтелмәячәкбез»** («әл-Мүэминүн», 37).

5. Һуд галәйһиссәләмне һәм мөэминнәрне төрлечә кимсетәләр, мыскыллыйлар. Аяти кәримәдә болай диелә:

وَقَالَ الْمَلَأُ مِنْ قَوْمِهِ الَّذِينَ كَفَرُوا وَكَذَّبُوا بِلِقَاءِ الْآخِرَةِ وَأَتْرَفْنَاهُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا مَا هَذَا إِلَّا بَشَرٌ مِثْلُكُمْ يَأْكُلُ مِمَّا تَأْكُلُونَ مِنْهُ وَيَشْرَبُ مِمَّا تَشْرَبُونَ. وَلَئِنْ أَطَعْتُمْ بَشَرًا مِثْلَكُمْ إِنَّكُمْ إِذًا لَخَاسِرُونَ

**«Кавеме арасыннан кяфер булган, ахирәт белән очрашуны ялган дип санаган һәм Без дөнья тормышында үзләренә нигъмәтләр биргән абруйлы затлар әйтте: “Бу – сезнең кебек бер кеше генә, ул сез ашаган нәрсәләрне ашый, сез эчә торган нәрсәләрне эчә. Үзегез кебек бер кешегә итагать итәсе булсагыз, һичшиксез, сез югалтучылар булырсыз”»** («әл-Мүэминүн», 33–34).

### Гыйбрәтле илаһи кисәтүләр

Һуд галәйһиссәләм кавеменең тәртибенә, гамәлләренә бик борчыла. Кулларын күтәреп, кайгыра-кайгыра, ул Җәнабел-Хакка ялвара. Шуннан соң бу кавемдәге хатын-кызлар кысыр кала, бала таба алмый башлый. Бу хәл ун ел дәвам итә. Халык Һуд галәйһиссәләмгә килергә мәҗбүр була, ләкин һаман да гафләттән, караңгылыктан арына алмый. Үзләре шаһит булган могҗизага карамастан, янә: «Син безгә берәр могҗиза күрсәт!» – диләр. Шуннан соң тагын да тәкәбберләнеп, «Әхкаф» сүрәсенең 22 нче аятендә әйтелгәнчә, мыскыллаулы, кимсетүле рәвештә Һудка тәкъдим ясыйлар: үзләре өчен бер газап җибәрелүен сорыйлар:

قَالُوا أَجِئْتَنَا لِتَأْفِكَنَا عَنْ آلِهَتِنَا فَأْتِنَا بِمَا تَعِدُنَا إِنْ كُنْتَ مِنَ الصَّادِقِينَ

**«Алар: “Син безгә безне илаһларыбыздан биздерергә дип килдеңме әллә? Әгәр тугры кешеләрдән булсаң, безгә вәгъдә иткәнне** (газапны) **китер”, – диделәр»** («әл-Әхкаф», 22).

Шуннан соң елгалар корый, бакчалар кибә, саргая. Телгә алынган «Ирәм бакчалары» юкка чыга. Алыптай гәүдәле бәндәләр бер телем икмәккә мохтаҗ хәлгә төшә.

Һуд галәйһиссәләм аларны кабат җыя һәм янә үгет-нәсыйхәт белән мөрәҗәгать итә: «Аллаһтан ярлыкау сорагыз!». Шуннан соң да кирелек белән кяферлектә калулары сәбәпле аларга ап-ачык кисәтү ясый:

قَالَ إِنِّي أُشْهِدُ اللَّهَ وَاشْهَدُوا أَنِّي بَرِيءٌ مِمَّا تُشْرِكُونَ. مِنْ دُونِهِ فَكِيدُونِي جَمِيعًا ثُمَّ لَا تُنْظِرُونِ.
إِنِّي تَوَكَّلْتُ عَلَى اللَّهِ رَبِّي وَرَبِّكُمْ مَا مِنْ دَابَّةٍ إِلَّا هُوَ آخِذٌ بِنَاصِيَتِهَا إِنَّ رَبِّي عَلَى صِرَاطٍ مُسْتَقِيمٍ.

**«...(Һуд) әйтте: “Һичшиксез, мин Аллаһны шаһит итеп чакырам, сез дә шаһит булыгыз: мин сезнең ширек кушканнарыгыздан еракмын. Аңардан башка берәүгә** (табынганнарыгыздан еракмын)**. Барыгыз бергә миңа тозак корыгыз һәм миңа һич кичектерү бирмәгез. Һичшиксез, мин үземнең дә, сезнең дә Раббыгыз булган Аллаһка тәвәккәл кылдым. Ул маңгай чәченнән тотып тормаган бер генә хәрәкәт итә алучы да юк. Һичшиксез, минем Раббымның юлы туры”»**[62] («Һуд», 54–56).

فَإِنْ تَوَلَّوْا فَقَدْ أَبْلَغْتُكُمْ مَا أُرْسِلْتُ بِهِ إِلَيْكُمْ وَيَسْتَخْلِفُ رَبِّي
قَوْمًا غَيْرَكُمْ وَلَا تَضُرُّونَهُ شَيْئًا إِنَّ رَبِّي عَلَى كُلِّ شَيْءٍ حَفِيظٌ

**«Әгәр йөз чөерсәгез, мин инде сезгә җибәрелгән нәрсәне сезгә ирештердем. Әмма Раббым** (теләсә) **сезнең урынга бер кавемне китерәчәк. Сез исә Аңа бернинди зарар да ясый алмаячаксыз. Һичшиксез, минем Раббым – һәрнәрсәне** (күзәтүче һәм) **саклаучы»** («Һуд», 57).

Бу аяти кәримәләрдән күренгәнчә, Һуд галәйһиссәләм мөшрик кавеменә ачык рәвештә фикерен белдерә:

«Барыгыз бергә җыелыгыз да, мине юк итү өчен, кулыгыздан килгәнчә, көчегез җиткәнчә, бөтенесен дә эшләгез. Күз ачып йомганчы кадәр дә көтеп тормагыз. Һичшиксез, мин сездән курыкмыйм, сезнең мине нишләтәчәгегез турында да уйламыйм, сезгә бөтенләй карамыйм, чөнки мин бары тик Аллаһка гына тәвәккәл кылам. Аңа гына таянам. Аңа таянган зат исә һич зыян күрмәс. Аннан башка һичкемнән курыкмыйм. Мин бары Аллаһка гына сыенам һәм Аңа гына гыйбадәт кылам».

Хәтта шушы сүзләр генә дә Һуд галәйһиссәләмнең Аллаһның колы һәм пәйгамбәре икәнлеген, ә аның каршындагыларның наданлык диңгезенә батуын һәм адашуда булганлыгын дәлилли. Һудның әлеге сүзләренә карамастан, дошманнары бернинди дә зыян сала алмый, аны дәгъватыннан баш тарттыруга ирешми. Бу да аның дәгъватының хаклыгын раслый.

Гад кавемен һидәят юлына бастыру өчен мондый янау-кисәтүләр генә җитми. Шулкадәр ярлылыкка төшүләренә, тормышларының авырлыгына карамастан, алар тәүбә-истигъфар кылып, Аллаһка һәм тәүхид иманга кайтудан барыбер баш тарталар. Чөнки гайре күп байлык заманыннан калган ваемсызлык, ялкаулык һәм азгынлык аркасында Аллаһка гыйбадәт кылудан

62. Ягъни Раббыбызның хөкемнәре һәм гамәлләре тулысынча дөрес. Ул хаксызлык һәм золымнан, хата-ялгышлардан азат, пакь.

бик ерагайган булалар. Алар шуны аңлый: әгәр пәйгамбәрләргә иярсәләр, бик күп хәрәм гамәлләрдән тыелырга, хаксызлыклар кылмаска, көчсезләрне җәберләмәскә туры киләчәк, чөнки хак дин булган тәүхид дине бер төркем чикләүләр кертә. Ә нәфескә буйсынып яшәүче бу бәндәләр дини кысаларга керергә теләмичә, һаман да гамьсез тормыш алып барырга, нәфес ләззәтләренә тиенеп яшәргә ниятлиләр.

**Пыран-заран китергән давыл**

Шуннан соң Аллаһ Тәгалә бу халыкка өч ел яңгыр җибәрми тора. Яңгыр өмет итеп, алар Мәккәгә бер делегация юллый. Озак та үтми күктә болытлар күренә. Гад кавемендә, күкне томалап алган болытларны күргәч: «Яңгыр килде!» – дип, барысы да сөенә. Хәлбуки, бу газап болытлары була.

Хәзрәти Һуд газаптан коткару өчен, кавемен соңгы тапкыр: «Иманга килегез!» – дип кисәтә. Ләкин алар барыбер гафиллектән котыла алмыйча: «Юк! Бу – яңгыр алдыннан килә торган болытлар!» – диләр.

Шул рәвешле Гад халкы соңгы илаһи кисәтүне дә күрми һәм ишетми. Ниһаять, үз вазифаларын башкаручы фәрештәләр күктә пәйда булган болытлар белән бөтен кавемне каплап ала. Чәршәмбе көнне иртән җил көчәя. Ул агачларны тамыры белән йолкып алырлык дәрәҗәдә көчле була. Тора-бара давылның дәһшәтле тавышы һәм салкыны тагын да куәтләнә. Аяти кәримәләрдә бу давыл түбәндәгечә телгә алына:

فَأَرْسَلْنَا عَلَيْهِمْ رِيحًا صَرْصَرًا فِي أَيَّامٍ نَحِسَاتٍ لِنُذِيقَهُمْ عَذَابَ الْخِزْيِ
فِي الْحَيوةِ الدُّنْيَا وَلَعَذَابُ الْآخِرَةِ أَخْزَى وَهُمْ لَا يُنْصَرُونَ

**«Шул сәбәпле, Без, дөнья тормышында аларга хурлык газабын татыттырыйк, дип, аларга бәхетсез көннәрдә туңдыра торган салкын бер җил җибәрдек. Ахирәт газабы исә тагын да хурлыклырак. Алар ярдәм күрмәячәкләр»** («Фуссыйләт», 16).

إِنَّا أَرْسَلْنَا عَلَيْهِمْ رِيحًا صَرْصَرًا فِي يَوْمِ نَحْسٍ مُسْتَمِرٍّ

**«Һичшиксез, Без дәвамлы шом булган беркөнне өсләренә бик салкын** (гөрелтеле) **җил җибәрдек»** («әл-Камәр», 19).

وَفِي عَادٍ إِذْ أَرْسَلْنَا عَلَيْهِمُ الرِّيحَ الْعَقِيمَ. مَا تَذَرُ مِنْ شَيْءٍ أَتَتْ عَلَيْهِ إِلَّا جَعَلَتْهُ كَالرَّمِيمِ

**«Гадтә дә** (гыйбрәтләр бар)**. Аларга кысыр җил җибәргән чагыбызда. Ул нинди дә булса нәрсә өстенә барса, аны череп таралган әйбер кебек итмичә туктамый иде»** («әз-Зарият», 41–42).

Бу давыл аркасында кешеләр чикерткәләр кебек һавада очып йөри башлый. Очып китмәс өчен, итәкләрен бер-берсенә бәйләп, боҗра ясыйлар, ләкин аларны бу да коткара алмый. Дөяләрнең, алып гәүдәле кешеләрнең очып йөргәнен күргәч, кайберләре өйләренә кереп качарга маташа. Ләкин аларны да шундый ук язмыш көтә, давыл салам чүбе кебек бу бәндәләрне тышка сибереп чыгара. Коръәни-Кәрим бу хәлне:

تَنْزِعُ النَّاسَ كَأَنَّهُمْ أَعْجَازُ نَخْلٍ مُنقَعِرٍ

**«Ул кешеләрне урыннарыннан куптарды. Әйтерсең, алар – тамырлары белән йолкып алынган хөрмә кәүсәләре»**, – дип сурәтли («әл-Камәр», 20).

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү җилгә әмер бирә һәм ком өемнәрен Гад халкы өстенә аудара. Давыл җиде төн, сигез көн дәвам итә. Һәм азгын кавем шундый аяныч язмышка дучар була. Гад кавеменең һәлакәте турында аяти кәримәләрдә болай дип хәбәр ителә:

سَخَّرَهَا عَلَيْهِمْ سَبْعَ لَيَالٍ وَثَمَانِيَةَ أَيَّامٍ حُسُومًا فَتَرَى الْقَوْمَ فِيهَا
صَرْعَى كَأَنَّهُمْ أَعْجَازُ نَخْلٍ خَاوِيَةٍ. فَهَلْ تَرَى لَهُمْ مِنْ بَاقِيَةٍ

**«Аллаһ** (давылга) **бер-бер артлы җиде төн, сигез көн буена котырырга ирек бирде. Син** (анда булсаң) **ул кавемнең эче буш хөрмә агачы кәүсәләре кебек җиргә түшәлгәннәрен күрер идең. Алардан калган берәр кешене күрәсеңме?»** («әл-Хәкка», 7–8).

وَقَطَعْنَا دَابِرَ الَّذِينَ كَذَّبُوا بِآيَاتِنَا وَمَا كَانُوا مُؤْمِنِينَ

**«…Безнең аятьләребезне ялганга санаган һәм иман китермәгән кешеләрне юк иттек»** («әл-Әгъраф», 72).

وَتِلْكَ عَادٌ جَحَدُوا بِآيَاتِ رَبِّهِمْ وَعَصَوْا رُسُلَهُ وَاتَّبَعُوا أَمْرَ كُلِّ جَبَّارٍ عَنِيدٍ. وَأُتْبِعُوا فِي
هٰذِهِ الدُّنْيَا لَعْنَةً وَيَوْمَ الْقِيَامَةِ، أَلَا إِنَّ عَادًا كَفَرُوا رَبَّهُمْ أَلَا بُعْدًا لِعَادٍ قَوْمِ هُودٍ

**«Бу Гад** (кавеме) **иде. Алар Раббыларының аятьләрен инкяр иттеләр, Аның илчесенә каршы чыктылар һәм алар һәр үзсүзле үҗәт кешенең әменә иярделәр. Алар бу дөньяда да, кыямәт көнендә дә ләгънәткә дучар булачаклар. Һичшиксез, Гад** (кавеме) **Раббыларын инкяр итте. Һудның кавеме булган Гад** (Аллаһның рәхмәтеннән) **ерак булсын»** («Һуд», 59–60).

Давыл килгән вакытта, Һуд галәйһиссәләм һәм тәүхид иманга килүчеләр, Аллаһның ярдәме һәм рәхмәте белән, илаһи газаптан коткарыла. Газап каршы чыгучылар өстенә әләгә. Аяти кәримәдә бу хакта:

وَلَمَّا جَاءَ أَمْرُنَا نَجَّيْنَا هُودًا وَالَّذِينَ آمَنُوا مَعَهُ بِرَحْمَةٍ مِنَّا وَنَجَّيْنَاهُمْ مِنْ عَذَابٍ غَلِيظٍ

**«Әмеребез килгәч, Һудны һәм аның янындагы иман китергән кешеләрне рәхмәтебез белән коткардык һәм аларны каты газаптан йолып калдык»**, – дип белдерелә («Һуд», 58).

Тәфсир галимнәре мондагы «рәхмәтебез белән коткардык» гыйбарәсенә түбәндәгечә аңлатма бирә.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Һуд галәйһиссәләмне һәм аңа ияргән мөэминнәрне, мәрхәмәтенең бер чагылышы буларак, давылдан саклый һәм коткарып кала. Шулай ук бу сүзләрдән аңлашылганча, бәндәләргә бирелгән нигъмәтләр һәм мал-байлыклар алар кылган гамәлләр өчен түгел, ә илаһи рәхмәт һәм мәрхәмәт сәбәпле җибәрелә.

Хәзрәти Гайшә радыйаллаһу ганһә әйтүенчә, җил иссә һәм күктә кара болыт күрсә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йөзе үзгәреп китә торган була, кайчак Ул аларга озаклап карап тора, өенә бер кереп, бер чыгып йөри башлый. Яңгыр яуганда исә, тынычланып кала. Болар бер борчылу билгесе була. Хәзрәти Гайшә радыйаллаһу ганһә сәбәбен белергә теләгәч, Рәсүл Әкрәм:

*«Мин каян белим, бәлки, бу кара болыт Гад кавеменә килгән кебек, газап китерәдер. Алар үзләре күргән болытны хәзер яңгыр яудырачак, дип уйлаган, әмма ул коточкыч газап алып килгән»* (Бохари, «Тәфсир», 46/2; Мөслим, «Истиска», 14–16).

Хәзрәти Гайшә анабыздан мондый хәдис тә тапшырылган:

Көчле җил искән чакта, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип дога кылды:

*«Аллаһым! Синнән бу җилнең, бу җил эчендә булган нәрсәләрнең һәм аңа йөкләнгән вазифаның хәерлесен сорыйм. Бу җилнең, аның эчендә булган нәрсәләрнең һәм йөкләнгән вазифаның явызлыгыннан Сиңа сыенам»* (Мөслим, «Истиска», 15).

Пәйгамбәребез һәрвакыт шундый уяу хәлдә була һәм өммәтенең дә шундый рухи халәтне саклавын тели.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, хушлашу хаҗын кылганда, Усфан үзәнлегенә килгәч, Хәзрәти Әбү Бәкердән:

*«Йә, Әбү Бәкер! Бу нинди үзәнлек иде?»* – дип сорый.

Хәзрәти Әбү Бәкер: «Усфан үзәнлеге», – дип җавап биргәч, Пәйгамбәребез Һуд галәйһиссәләмнең, биленә калын комач бәйләгән, билдән югары чуар җилән белән капланган хәлдә, йөгәне хөрмәт сүсләреннән үрелгән, кызыл

төстәге яшь дөя өстендә тәлбия әйтеп (Аллаһны зурлап) хаҗ кылырга шушыннан узып киткәнлеге турында сөйләп бирә (Әхмәд ибне Ханбәл, «Муснәд», I, 232).

Гад кавеме һәлак ителгәч, Хәзрәти Һуд галәйһиссәләм үзенә ияручеләр белән бергә Мәккәгә килә һәм вафатына кадәр шунда яши.

**Хәзрәти Һуд галәйһиссәләмнең могҗизалары**

1. Аллаһның рөхсәте белән җилләрне үзе теләгән якка юнәлтә.

Һуд галәйһиссәләмнән могҗиза сораган кавеменә: «Сез нинди могҗиза телисез соң?» – дигәч, җилне үзләре теләгән якка борып җибәрергә кушалар. Хәзрәти Һуд галәйһиссәләм җилне алар кушкан юнәлешкә бора.

Җәнабел-Хакның бу могҗизасын күреп тә, иманга килмәгәннәре өчен, ахыр чиктә Гад кавеменең җил белән һәлак ителүенә никадәр зур гыйбрәт салынган! Бу җил, Коръәни-Кәрим сүзләре белән әйткәндә, «рих-и сарсар» (гөрелтеле һәм дәһшәтле давыл) дип атала.

2. Йонны ефәккә әйләндерә, ягъни ялтырап торган рәвешкә китерә.

3. Көчле яңгырлар яуганда, юлда йөреп булмый. Һуд галәйһиссәләм дога кыла һәм юлларда ышык урыннар барлыкка килә. Яңгыр тәмамланганчы халык, шуларда ышыкланып, көтеп тора.

Үткән заманнардагы пәйгамбәрләр һәм аларның кавемнәре белән бәйле кыйссалар Коръәни-Кәримдә иман ияләре гыйбрәт алсын өчен бәян ителә. Борынгыдагы пәйгамбәрләрнең һәр эш-гамәле мөселманнар өчен дә өлге, барыр юл булып тора. Һуд галәйһиссәләм кыйссасына бу тарафтан карасак, бик күп үрнәк алырлык гамәлләр күрәбез.

Хәзрәти Һуд галәйһиссәләм – Аллаһ юлына бар күңеле белән сарылган, хөрмәткә лаек зат ул. Әйтәсе сүзен уйлап-чамалап кына әйтә торган була. Кавеме аны тилелектә гаепләгәндә, үзенең акылсыз түгеллеген, аларны кисәтү өчен Аллаһ тарафыннан җибәрелгән бер илче икәнлеген сөйләү белән чикләнә. Явызлыкка явызлык белән җавап бирмәгән кебек, кавеменең сүзенә дә йомшак мөнәсәбәт күрсәтә. Аларга Аллаһ биргән нигъмәтләр турында искә төшерә һәм, бу нигъмәтләргә шөкер итү өчен, Аллаһ кушканнарны үтәү кирәклеген аңлата. Бу үгет-нәсыйхәте өчен халкыннан бернинди акча сорамаганын да белдерә.

Галәйһиссәләм!

***Хәзрәти Һуд галәйһиссәләм***





ХӘЗРӘТИ

# Салих

*галәйһиссәләм*

### *Азгынлык һәм бозыклыклары аркасында зилзиләләр белән пыран-заран китерелгән Сәмуд кавеме пәйгамбәре*

# ХӘЗРӘТИ САЛИХ

### *галәйһиссәләм*

Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмнең унтугызынчы буын оныгы булган Салих галәйһиссәләм пәйгамбәр итеп Сәмуд кавеменә җибәрелә.

Бер риваятькә күрә, Нух, Һуд, Салих һәм Шөгаеб галәйһимәс-сәләмнәрнең каберләре Мәккәдә Зәмзәм чишмәсе белән Хаҗәри Әсвәд (Кара таш) арасында (Карагыз: Әзракый, «Ахбару Мәккә», I, 73).

**Сәмуд кавеме**

Сәмуд кавеменең һәлакәте дә телдән-телдән күчә, дастаннарга керә. Иманга килмәгән һәм хисапсыз азгынлык кылып, илаһи чикләрне бозганга күрә һәлак ителгән бу кавем турында Коръәни-Кәримнең төрле сүрәләрендә гыйбрәт өчен искә алына.

Сүз Нух галәйһиссәләмнең улы Сам нәселеннән килгән Сәмуд кавеме турында бара. Хәзрәти Һудның вафатыннан соң, Сәмудның оныклары Төньяк Гарәбстан төбәгенә, Димәшкъ белән Хиҗаз арасындагы Хиҗр дип аталган җиргә урнаша. Соңрак моннан Гад кавеме яшәгән төбәккә күченәләр. Сәмудның нәселе, зураеп, тулы бер кавемгә әйләнә. Аларга «Гади Сани» (Икенче Гад) исеме бирелә.

Сәмуд кавеме дә, вакытлар узу белән, Гад халкы биләгән нигъмәтләргә ия була. Ләкин алар да, Гад кавеме кебек, ваемсызлык йокысына чумып, туры юлдан яза. Бу халык гафләт исереклеге тәэсирендә Гад кавеменең һәлакәтен азгынлыклары сәбәпле җибәрелгән илаһи газапка түгел, ә башка сәбәпләргә бәйләп аңлатырга маташалар:

«Гад кавеме ныклы биналар төземәгәнгә күрә һәлак булган. Чөнки алар өйләрен ком өстенә салган. Без исә ныклы кыялар өстенә салдык. Безгә килгән давыллардан бернинди дә зарар күрмибез…» – диләр. Сәмуд кешеләре үзләренә зур-зур сарайлар төзи. Ташларны уеп, йортларын төрле рәвештә салалар. Сарайларын төрлечә бизиләр. Тәүхид динне онытып, Аллаһка тиңдәшләр табалар һәм үзләре ясаган потларны үзләренә тәңре итеп куялар.

Кавемне Җүнда исемле бәндә җитәкли. Гад кавеме язмышыннан гыйбрәт алмаган Сәмуд халкы, үзара килешеп, Җүндадан үзләре өчен бер кавемдә дә булмаган берәр пот ясавын сорый. Җүнда бу үтенечтән бик канәгать кала.

Тауларга барып, зур бер кыяны юнарга, чокырга керешәләр. Бу кыяга күз, сыер күкрәге, ат аягы кебек рәвешләр биреп, аны алтын-көмеш, төрле асылташлар белән бизиләр. Аннары исә каршына басып, сәҗдә кылалар.

Шушы поттан соң Сәмуд кешеләре үзләренә бер потханә төзи. Вәдд, Җәдд, Хәд, Шәмс, Мәнаф, Лат исемле потлар булдырып, шуларга табына башлыйлар.

Бу вакытта Салих галәйһиссәләм кавем әгъзасы була. Сәүдә белән шөгыльләнә, кул көче белән тормыш алып бара. Салих галәйһиссәләм чын-чынлап хөрмәткә лаек зат була. Турылыгы, игелеклеге һәм зирәклеге өчен кавеме аны бик ярата. Киләчәктә аңа зур өметләр баглыйлар, хәтта үзен кавем башлыгы итеп тә куярга ниятлиләр. Әмма Аллаһ Тәгалә Салих галәйһиссәләмгә пәйгамбәрлек вазифасын йөкли.

**Дәгъватка керешү**

Салих галәйһиссәләм кырык яшенә җиткәндә, Җәбраил галәйһиссәләм аңа пәйгамбәрлеге турында хәбәр алып килә. Салих галәйһиссәләм башта куркып кала. Әмма Хәзрәти Җәбраил: «Әй, Салих! Бар, кавемне тәүхид дингә чакыр!» – дип боера. Аннары: «Әй, Салих! Син Нух һәм Һуд заманында булмаган нәрсәләрне дә күрәчәксең!» – дип, күккә күтәрелеп китә.

Әлеге хәлдән соң Салих галәйһиссәләм, әүвәл кавем башлыгы Җүнда янына барып, аны тәүхидкә өнди. Җүнда бу чакыруга гаять инсафлы һәм акыллы җавап бирә. «Бу хакта кавемемә әйтим әле», – ди ул. Аннары Җүнда кавемен җыя да халыкка Салих галәйһиссәләмнең пәйгамбәрлеге һәм тәүхид дин турында хәбәр җиткерә. Кавемдәшләре исә: «Әй, Җүнда, килеп үзе сөйләсен!» – диләр. Шуннан соң Салих галәйһиссәләм чыгып, дәгъват кыла. Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Салихның кавемен туры юлга өндәве турында болай диелә:

وَإِلَى ثَمُودَ أَخَاهُمْ صَالِحًا قَالَ يَا قَوْمِ اعْبُدُوا اللَّهَ مَا لَكُمْ مِنْ إِلَهٍ غَيْرُهُ هُوَ أَنْشَأَكُمْ مِنَ
الْأَرْضِ وَاسْتَعْمَرَكُمْ فِيهَا فَاسْتَغْفِرُوهُ ثُمَّ تُوبُوا إِلَيْهِ إِنَّ رَبِّي قَرِيبٌ مُجِيبٌ

**«Сәмудка исә кардәшләре Салихны** (җибәрдек). **Ул әйтте: “И, кавемем! Аллаһка гыйбадәт кылыгыз, сезнең Аннан башка һичбер илаһыгыз юк. Ул сезне туфрактан яралтты һәм сезне анда урнаштырды. Сез Аңардан ярлыкау сорагыз, шуннан Аңа тәүбә кылыгыз. Һичшиксез, минем Раббым** (колларына) **бик якын,** (догаларына) **җавап бирүче”»** («Һуд», 61).

«Шугара» сүрәсендә дә бу вакыйга белән бәйле аятьләр бар:

كَذَّبَتْ ثَمُودُ الْمُرْسَلِينَ.إِذْ قَالَ لَهُمْ أَخُوهُمْ صَالِحٌ أَلَا تَتَّقُونَ. إِنِّي لَكُمْ رَسُولٌ أَمِينٌ.
فَاتَّقُوا اللَّهَ وَأَطِيعُونِ. وَمَا أَسْأَلُكُمْ عَلَيْهِ مِنْ أَجْرٍ إِنْ أَجْرِيَ إِلاَّ عَلَى رَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Сәмуд** (кавеме) **бөтен җибәрелгәннәрне ялганчы дип санады. Кардәшләре Салих аларга әйтте: “**(Аллаһка каршы килүдән) **һич курыкмыйсызмы? Һичшиксез, мин – сезгә ышанычлы бер илчемен. Аллаһтан куркыгыз һәм миңа итагать итегез. Мин бит сездән моның** (тәблигым) **өчен түләү сорамыйм. Минем әҗерем – Аллаһта гына”»** («әш-Шугара», 141–145).

Хәзрәти Салих галәйһиссәләм шул рәвешле дәгъват эшен ачыктан-ачык башкарырга керешкәч, кавеменең аңа карата мөнәсәбәте мизгел эчендә үзгәрә. Халык Салих галәйһиссәләмгә каршы туплана башлый.

Әүвәлге пәйгамбәрләрдәге кебек, Хәзрәти Салихның чакыруын һәм тәүхид динне бик азлар гына кабул итә. Бүтәннәре исә дәгъватны кире кага:

قَالُوا يَا صَالِحُ قَدْكُنْتَ فِينَا مَرْجُوًّا قَبْلَ هَذَا أَتَنْهَانَا أَنْ نَعْبُدَ
مَا يَعْبُدُ آبَاؤُنَا وَإِنَّنَا لَفِي شَكٍّ مِمَّا تَدْعُونَا إِلَيْهِ مُرِيبٍ

**«И, Салих! Элек син арабызда өмет багланган бер кеше идең. Әллә син** (хәзер) **безне аталарыбыз табынган нәрсәләргә табынудан тыясыңмы? Һичшиксез, без син безне дәгъват иткән нәрсәләрдән шомлы икеләнү эчендәбез»** («Һуд», 62).

قَالَ يَا قَوْمِ أَرَأَيْتُمْ إِن كُنْتُ عَلَى بَيِّنَةٍ مِنْ رَبِّي وَآتَانِي مِنْهُ رَحْمَةً
فَمَنْ يَنْصُرُنِي مِنَ اللَّهِ إِنْ عَصَيْتُهُ فَمَا تَزِيدُونَنِي غَيْرَ تَخْسِيرٍ

**«**(Салих) **әйтте: “И, кавемем! Әгәр мин Раббымнан** (бирелгән) **ап-ачык бер дәлилгә таянган булсам, һәм Ул миңа Үз хозурыннан сезгә күренмәгән бер рәхмәт** (пәйгамбәрлек) **биргән булса? Инде мин Аңа каршылык кылган булсам, кем мине Аллаһтан** (Аның газабыннан) **саклый алыр? Сез миңа зарардан башка бернәрсә дә арттырган булмассыз!”»** («Һуд», 63).

قَالَ يَا قَوْمِ لِمَ تَسْتَعْجِلُونَ بِالسَّيِّئَةِ قَبْلَ الْحَسَنَةِ لَوْلَا تَسْتَغْفِرُونَ اللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ

**«**(Салих) **әйтте: “Әй, кавемем! Күркәм нәрсәдән алда начар нәрсәне ни өчен ашыктырасыз? Сез, рәхмәт ителүегез өчен, Аллаһтан ярлыкау сорасагыз иде”»** («ән-Нәмел», 46).

Салих галәйһиссәләмнең әлеге хикмәтле һәм хакыйкатьле нәсыйхәтенә карамастан, кавеме хәтта Аны сихерләнгән алдакчы дип гаепләү кабахәтләгенә бара:

قَالُوا إِنَّمَا أَنْتَ مِنَ الْمُسَحَّرِينَ

**«Алар әйттеләр: “Син бит сихерләнгән кешеләрдәнсең!”»** («әш-Шугара», 153).

Соңыннан үзара болай дип сөйләшәләр:

فَقَالُوا أَبَشَرًا مِنَّا وَاحِدًا نَتَّبِعُهُ إِنَّا إِذًا لَفِي ضَلَالٍ وَسُعُرٍ

**«”Арабыздан бер кешегә иярәбезме әллә? Ул тәкъдирдә без адашу һәм Ут эчендә булырбыз!”»** – диләр» («әл-Камәр», 24).

ءَأُلْقِيَ الذِّكْرُ عَلَيْهِ مِنْ بَيْنِنَا بَلْ هُوَ كَذَّابٌ أَشِرٌ

**«”Арабыздан аңа вәхи калдырылдымы? Юк! Ул – ялганчы, тәкәббер!” – дип сүзләрен дәвам итәләр»** («әл-Камәр», 25).

Сәмуд кавеменең мондый наданнарча гаепләвенә Җәнабел-Хак бик куркыныч янау белән җавап бирә:

سَيَعْلَمُونَ غَدًا مَنِ الْكَذَّابُ الْأَشِرُ

**«Иртәгә ялганчы һәм тәкәббернең кем икәнен беләчәкләр!»** («әл-Камәр», 26).

قَالَ عَمَّا قَلِيلٍ لَيُصْبِحُنَّ نَادِمِينَ

**«Бик аз вакыттан соң алар һичшиксез үкенәчәкләр!»** («әл-Мүэминүн», 40).

Салих пәйгамбәр сабыр итә, өметсезлеккә төшми. Һичнигә карамастан, хакыйкатьтән йөз чөергән кавемен потлардан читләштерергә тырыша. Аларга үгет-нәсыйхәт бирә, дәгъватын дәвам итә:

أَتُتْرَكُونَ فِي مَا هَاهُنَا آمِنِينَ. فِي جَنَّاتٍ وَعُيُونٍ. وَزُرُوعٍ وَنَخْلٍ
طَلْعُهَا هَضِيمٌ وَتَنْحِتُونَ مِنَ الْجِبَالِ بُيُوتًا فَارِهِينَ. فَاتَّقُوا اللَّهَ وَأَطِيعُونِ .
وَلَا تُطِيعُوا أَمْرَ الْمُسْرِفِينَ. الَّذِينَ يُفْسِدُونَ فِي الْأَرْضِ وَلَا يُصْلِحُونَ

«(Әй, кавемем!) **Сез биредә имин кешеләр буларак калдырылачаксызмы әллә? Бакчалар һәм чишмәләр арасында. Игеннәр арасында һәм**

**җимешләре салынып торган хөрмәлекләр арасында.** (Шулай дип уйлап) **тәкәбберләнеп тауларда өйләр тишәсез. Аллаһтан куркыгыз һәм миңа итагать итегез! Ул исрафчыларның** (кяферләрнең) **әмеренә буйсынмагыз. Алар җирдә бозыклык тараталар һәм** (үзләрен дә, әйләнә-тирәдәгеләрне дә) **төзәтергә тырышмыйлар»** («әш-Шугара», 146–152).

Хәзрәти Салихка комачаулый алмаганлыкларын аңлагач, Сәмуд халкы аңа турыдан-туры аяк чалудан баш тарта. Ләкин Салих галәйһиссәләмгә ышанган мөэминнәрне юлдан яздырырга маташа башлыйлар. Сәмуд халкы Аллаһ илчесен ялгыз калдырырга тели. Мөэминнәргә:

أَتَعْلَمُونَ أَنَّ صَالِحًا مُرْسَلٌ مِنْ رَبِّهِ

**«...Сез Салихны Раббысыннан җибәрелгән бер кеше дип беләсезме әллә?..»** («әл-Әгъраф», 75), – диләр. Хак иман бәхетен тойган бәндәләр исә:

إِنَّا بِمَا أُرْسِلَ بِهِ مُؤْمِنُونَ

**«...Һичшиксез, без аның белән иңдерелгән нәрсәгә иман китердек»** («әл-Әгъраф», 75), – дип җавап кайтаралар. Һич шөбһәгә урын бирмәгән мондый ихлас иман каршында Сәмуд кавеменең кяферләре аптырап кала.

إِنَّا بِالَّذِي آمَنْتُمْ بِهِ كَافِرُونَ

**«...Сез иман китергән нәрсәне инкяр итәбез»**, – дип, алар көферлек сазлыгыннан чыгуда кирелек күрсәтәләр («әл-Әгъраф», 76). Бу кяферләр Хәзрәти Салихны сихерчелектә гаепләп, халыкны да аның динен кире кагарга мәҗбүр итәргә тырыша. Һич иманга килмәгән Сәмуд кавеме, үз акыллары җиткән кадәр, төрле сәбәпләр, сылтаулар табалар. Салих галәйһиссәләмгә: «Син безнең малларыбызга хуҗа булырга, аларны кулыбыздан тартып-талап алырга телисең. Безнең башлык булырга телисең!» – диләр. Аннары, бик түбән дәрәҗәдәге мантыйк белән фикер йөртеп: «Безнең потларыбыз бар. Хәзер без күзгә күренеп торганнарны ташлап, күренмәгән Аллаһка табыныйкмы?!» – дип белдерәләр. Сүзләрен болай дип дәвам итәләр:

«Күзгә күренмәгән Аллаһ сиңа ни рәвешле вазифа йөкли соң?!»

«Әгәр хак сүзләр сөйлисең икән, безгә һичкем башкара алмаган берәр нәрсә эшләп күрсәт!»

مَا أَنْتَ إِلَّا بَشَرٌ مِثْلُنَا فَأْتِ بِآيَةٍ إِنْ كُنْتَ مِنَ الصَّادِقِينَ

**«Син бит безнең кебек бер кеше! Әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсаң, бер аять** (могҗиза) **китер!»** («әш-Шугара», 154).

**Дөя могҗизасы**

Салих галәйһиссәләм кавеменең наданлыгына һәм ваемсызлыгына бик кайгыра. Күпмедер вакытка ул халкын ташлап чыгып китә. Җәнабел-Хак аның килеш кыяфәтен үзгәртә һәм Хәзрәти Салих галәйһиссәләм кавеменә яңа рәвештә кайта. Аның кырысланган йөз кыяфәте кавемне куркыта.

Салих галәйһиссәләм, кавем башлыгы Җүнда янына юл тота. Җүнда:

«Әгәр хак нәрсә сөйлисең икән, сиңа имтихан уздырабыз!» – ди. «Әл-Катибә» атамасы белән билгеле бер кыя була. Җүнда, шул кыяны күздә тотып, шарт куя: «Синең белән шунда барырбыз. Синең илаһың шул кыядан кызыл йонлы, балаларга җыенган бер ана дөя чыгарсын! Баласының төсе дә анасыныкы кебек булсын!»

Кавем халкы, мыскыллы үрти-үрти, өстәп куя: «Сөте җәен салкын, кышын җылы булсын! Бу сөтне эчкән һәр авыру шифа тапсын, фәкыйрь зат исә ярлылыктан котылсын!»

Ул чорда кызыл төстәге дөя бу кавем өчен иң кыйммәтле нәрсә санала. Шуңа күрә Салих галәйһиссәләмгә кыядан кызыл йонлы дөя чыгарырга кушалар.

Бөтен Сәмуд кавеме җыела. Салих галәйһиссәләм намазга баса һәм Җәнабел-Хакка ялвара. Шулчак кыя зурая башлый. Ыңгырашкан тавышлар чыгара һәм шуннан соң аның эченнән « لَا اِلَهَ اِلَّا اللهُ صَالِحٌ نَبِيُّ اللهِ » (Аллаһтан башка илаһ юк, Салих галәйһиссәләм – Аллаһның пәйгамбәре) дип, кызыл төстәге бер дөя килеп чыга.

Җүнда Салих галәйһиссәләмне маңгаеннан үбә һәм йөз кеше белән бергә тәүхид динне кабул итә. Аннары ул кавеменә мөрәҗәгать итә: «Әй, кавемем! Бу сукырлык тәмам! Мин Аннан башка табынырлык һичбер зат булмаган, тиңе һәм охшашы булмаган Аллаһка һәм Аның пәйгамбәре Хәзрәти Салихка иман китердем!»

Потханә башлыгы моның белән килешергә теләми: «Сихер булган нәрсәгә бик тиз бирeләсез! Мин сезгә аннан да зурракны күрсәтәчәкмен!» Шул рәвешле яңа иман китергән бәндәләрнең йөрәкләрендәге теләкне үзгәртүгә ирешә, мондыйлар арасында Җүнданың кардәше дә була. Потханә башлыгы Җүнданың таҗын аның кардәшенә кидереп: «Моннан соң син безнең башлыгыбыз!» – ди.

Җүнда исә өенә кайтып, андагы бөтен потларны җимерә. Үзенең мал-мөлкәтен тәүхид динне кабул иткән мөэминнәргә өләшә. Үзе исә каты һәм йоны укмашып беткән кием кия. Аннары дәгъват эшенә керешә, Салих галәйһиссәләмнең төп ярдәмчеләреннән берсенә әйләнә. Имансыз потпәрәстләр Җүндага: «Каһәр төшсен сиңа! Син дә Салихның сихеренә бирелдең!» – диләр.

Җүнда исә аларның сүзләреннән курыкмый һәм Салих галәйһиссәләм янын-нан китми. Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Салихка:

إِنَّا مُرْسِلُوا النَّاقَةِ فِتْنَةً لَهُمْ فَارْتَقِبْهُمْ وَاصْطَبِرْ

**«Һичшиксез, Без аларга сынау булсын, дип, ана дөяне җибәрәбез. Син аларны күзәт һәм сабыр ит!»** – дип боера («әл-Камәр», 27).

Салих галәйһиссәләм илаһи вәхи нигезендә ул дөя өчен шарт куя:

وَيَا قَوْمِ هَٰذِهِ نَاقَةُ اللَّهِ لَكُمْ آيَةً فَذَرُوهَا تَأْكُلْ فِي أَرْضِ اللَّهِ وَلَا تَمَسُّوهَا بِسُوءٍ فَيَأْخُذَكُمْ عَذَابٌ قَرِيبٌ

**«И, кавемем! Бу – сезгә бер могҗиза буларак, Аллаһның ана дөясе. Аны Аллаһның җирендә калдырыгыз, ашасын** (эчсен)**. Аңа явызлык белән кагылмагыз, юкса, сезне бик якын бер газап тотачак»** («Һуд», 64).

قَالَ هَٰذِهِ نَاقَةٌ لَهَا شِرْبٌ وَلَكُمْ شِرْبُ يَوْمٍ مَعْلُومٍ. وَلَا تَمَسُّوهَا بِسُوءٍ فَيَأْخُذَكُمْ عَذَابُ يَوْمٍ عَظِيمٍ

**«**(Салих) **әйтте: “Бу** (сез сораган могҗиза) **ана дөя ки, билгеләнгән көнне су эчү – аның хакы, һәм эчү вакыты** (билгеле бер көнне) **– сезнеке. Аңа явызлык белән кагылмагыз, югыйсә, олуг көннең газабы сезне тотачак”»** («әш-Шугара», 155–156).

Дөя баласы белән утлап йөри һәм Аллаһны тәсбих итә. Башка хайваннар аның кыяфәтеннән куркып кача. Дөя үз-үзен тотышы белән: «Кемгә сөт кирәк, килсен дә алсын!» – дип ишарәли. Сәмуд кешеләре, килеп, савытларын тутырып китәләр. Дөя, су эчкән саен, тәсбихен дәвам итә. Аның сөтен эчкән мөэминнәр авырулардан шифа таба.

### Рәхмәтсезлек

Олуг могҗиза – кыядан дөя чыгу вакыйгасыннан соң гаҗизлекләренә бик борчылган кяферләр, ул дөяне үтерергә ниятли, ләкин бу җинаятьтән соң илаһи газап килүеннән куркалар. Андый куркуларга карамастан, Сәмуд кавемендәге ике хатын, көтүләренә зыян китерә, дигән сылтау белән, ул дөяне үтертү өчен имансыз бәндәләрне гел котыртып йөриләр. Әлеге ике хатынның берсе Үнәйзә бинте Ганәм була. Үзе өлкән яшьләрдә, тик бик чибәр кызлары бар. Икенчесе исә Мөхәййа исемле бай да, чибәр дә хатын була.

Хатыннарның икесе дә кяферләрдән теге дөяне үтерттерергә тели, чөнки аларның мал көтүе, Салих галәйһиссәләмнең дөясе су эчкән вакытта, су эчә алмый тора, чөнки шарт буенча, маллар чиратлап су эчәргә тиеш була: бер көнне кыядан чыккан дөя белән баласы, икенче көнне – башка хайваннар.

Мөхәййа әтисенең бертуганының улы Мыстаны чакырып ала да: «Бу дөяне үтерсәң, синең белән өйләнешәм! Һәрнәрсәм синеке булыр!» – ди.

Мыста мондый тәкъдимгә ризалаша, тик аңа бирәр ярдәмче кирәк була. Потка табынучы Кытар исемле берәүне таба. Аңа исә Үнәйзәнең кызлары тәкъдим ителә. Аларның берсен сайлагач, Кытар да бу пычрак эшкә ризалык бирә. Әлеге ике кабахәт, үзләре кебек тагын берничә бәндәне табып, барлыгы тугызау җыела. Дөяне үтерер өчен, имансыз потпәрәстләрне төрлечә алдап-йолдап котырталар. Аллаһ Тәгалә алар хакында болай дип белдерә:

وَكَانَ فِي الْمَدِينَةِ تِسْعَةُ رَهْطٍ يُفْسِدُونَ فِي الْأَرْضِ وَلَا يُصْلِحُونَ

**«Ул шәһәрдә гаиләләрдән тугыз кеше** (юлбасарлар төркеме) **бар иде, алар җирдә бозыклык чыгаралар,** (игелек ягына) **төзәтергә тырышмыйлар иде»** («ән-Нәмел», 48).

Бу тугыз кеше засада оештыра. Мыста, җәядән атып, дөяне яралый. Кытар һәм аның янындагылар дөя өстенә ташлана:

فَعَقَرُوا النَّاقَةَ وَعَتَوْا عَنْ أَمْرِ رَبِّهِمْ

**«Алар** (ул кешеләр) **Раббыларының әмереннән тәкәбберләнделәр һәм дөяне** (аякларын кисеп егып) **суйдылар…»** («әл-Әгъраф», 77).

Дөя баласы өркеп, тауларга кача. Бер риваятькә күрә, аны да суеп, итен ашыйлар. Салих галәйһиссәләм бу хакта ишеткәч, бик кайгыра. Ул дөя янына барып, тыела алмыйча елый. Кавеме өчен һидәят сорап дога кылганда, кавеме Аңа мондый тәкъдим ясый:

وَقَالُوا يَا صَالِحُ ائْتِنَا بِمَا تَعِدُنَا إِنْ كُنْتَ مِنَ الْمُرْسَلِينَ

**«"…Әй Салих! Әгәр чыннан да илчеләрдән булсаң, вәгъдә иткәнеңне** (янаган газабыңны) **безгә китер!" – диләр»** («әл-Әгъраф», 77).

فَتَوَلَّى عَنْهُمْ وَقَالَ يَا قَوْمِ لَقَدْ أَبْلَغْتُكُمْ رِسَالَةَ رَبِّي وَنَصَحْتُ لَكُمْ وَلَكِنْ لَا تُحِبُّونَ النَّاصِحِينَ

**«**(Салих) **алардан йөз чөерде дә: "И, кавемем! Мин сезгә Раббымның вәхиен ирештердем һәм сезгә игелек кенә теләдем, ләкин сез игелек теләүчеләрне сөймисез", – диде»** («әл-Әгъраф», 79).

قَالُوا اطَّيَّرْنَا بِكَ وَبِمَنْ مَعَكَ قَالَ طَائِرُكُمْ عِنْدَ اللَّهِ بَلْ أَنْتُمْ قَوْمٌ تُفْتَنُونَ

**«Алар** (Салихка) **әйттеләр: "Без синдә һәм синең яндагы кешеләрдә куркыныч билгеләр күрдек".** (Салих) **әйтте: "Сезнең шомлануыгыз – Аллаһ хозурында. Әйе, сез – сыналган бер кавемсез"»** («ән-Нәмел», 47).

Хәзрәти Салих галәйһиссәләм: «Ләкин сез үгетләүчеләрне сөймисез!» – дигән сүзләр белән кавемен шелтәли. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәл-

ләм дә Бәдер явында үтерелеп, коеларга күмелгән корәешлеләргә өч төннән соң болай дип мөрәҗәгать итә:

«Әй, калиб[63] әһле! Раббыгыз сезгә вәгъдә иткән нәрсәләрнең чын икәнен күрдегезме? Һичшиксез, мин Раббымның миңа вәгъдә иткән нәрсәләрнең чын икәнлеген күрдем».

Аннары аларга кабат аваз сала:

«Пәйгамбәрегезгә карата мөгамәләгез шундый начар иде. Бәндәләрнең бер өлеше минем сүзләремне раслаганда, сез мине ялганчыга чыгардыгыз. Бәндәләрнең бер өлеше мине кочакларына алганда, сез мине туган җиремнән кудыгыз. Бәндәләрнең бер өлеше миңа булышканда, сез минем белән сугыштыгыз. Пәйгамбәрегезгә карата мөгамәләгез нинди начар иде!»

Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе:

«Йә, Рәсүлүллаһ, черегән, үләксәгә әйләгән затларга дәшәсезмени?» – дигәч, Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Җаным кодрәтле кулында булган Аллаһ белән ант итәм, мин сөйләгән сүзләрне алар сездән дә яхшырак ишетәләр, ләкин җавап бирерлек хәлдә түгелләр»* – дип җавап бирә (Мөслим, «Җенаиз», 26/932; Әхмәд ибне Ханбәл, «Муснәд», III, 104).

Шулай ук Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый хәдисе риваять кылына, Хиҗр дип аталган төбәктән узганда, Ул болай ди:

*«Могҗиза сорамагыз. Салих галәйһиссәләмнең кавеме пәйгамбәрләреннән могҗиза сорады (Алар теләгән могҗиза чынга ашты – кыядан дөя чыкты). Дөя шушы юлдан сулыкка бара, шушы юлдан кире кайта иде. Алар, Раббыларының әмеренә каршы барып, ул дөяне суйдылар. Дөя бер көнне аларның суын эчә иде, алар исә бер көн аның сөтен эчә иде. Ахырда дөяне суйдылар да аларны куркыныч тавыш эләктереп алды. Аллаһ шул куркыныч тавыш белән аларны һәлак итте. Бары Мәсҗиди Хәрамдә калган бер кеше генә исән калды».*

Әсхәбе кирам:

«Ул үлмәгән кеше кем иде, йә, Аллаһның Рәсүле?» – дип кызыксынгач, Пәйгамбәребез:

*«Ул Әбү Ригал иде. Хәрамнән чыккач, кавеменең башына төшкән бәла-каза аңа да эләкте»*, – дип сөйләп бирә (Әхмәд ибне Ханбәл, «Муснәд», III, 296; Вакыйди, «Мәгази», III, 1007–1008).

63. Калиб – кое, чокыр.

**Азгын кавемнең куркыныч тавыш һәм зилзилә белән һәлак ителүе**

Кавемен төзәлү юлына кертер һәм аларны шул вакыттагы аяныч хәлләреннән коткарыр өчен, Хәзрәти Салих галәйһиссәләм куйган тырышлык бер нәтиҗә дә бирми, киребеткән төркем пәйгамбәрләрен үҗәтләнеп кире кага. Моның табигый нәтиҗәсе буларак, алар илаһи газапка дучар ителә. Иң ахырда, үзләренә газап җибәрелгәнче, тагын өч көн көтеп торачаклары турында хәбәр кылә:

فَقَالَ تَمَتَّعُوا فِي دَارِكُمْ ثَلَاثَةَ أَيَّامٍ ذٰلِكَ وَعْدٌ غَيْرُ مَكْذُوبٍ

**«**(Салих) **әйтте: "Өйләрегездә өч көн хозурланыгыз. Бу – ялган булмаган бер вәгъдә"»** («Һуд», 65).

Риваятькә күрә, әлеге өч көн чәршәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомгага туры килә. Беренче көнне аларны йөзләре саргаерга, икенче көнне кызарырга, өченче көнне каралырга, ә дүртенче көнне исә алар һәлак ителергә тиеш була. Ул төннең иртәсендә гаҗәп хәлләр күзәтелә. Дөя баскан җирләрдән кан бәреп чыга. Яфраклар кызара. Кое суы кандай кып-кызыл төскә керә. Бәдбәхетләрнең йөзләре сап-сары булып үзгәрә. Дөяне үтергән тугыз кеше: «Салих безне сихерли! Аны да, гаиләсен дә үтерик!» – диләр. Аларның әлеге мәкере турында аяти кәримәдә дә хәбәр ителә:

قَالُوا تَقَاسَمُوا بِاللَّهِ لَنُبَيِّتَنَّهُ وَأَهْلَهُ ثُمَّ لَنَقُولَنَّ لِوَلِيِّهِ مَا شَهِدْنَا مَهْلِكَ أَهْلِهِ وَإِنَّا لَصَادِقُونَ

**«**(Аллаһ белән ант итеп, бер-берсенә) **әйттеләр: "Аңа һәм гаиләсенә бер төнне һөҗүм итәчәкбез** (барысын да үтерәбез)**, аннары, һичшиксез, иң якын туганына** (аны яклаячак затларга)**. Без аның** (Салихның) **гаиләсенең һәлак булуына хәтта шаһит та булмадык, һичшиксез, без – дөресен сөйләгән кешеләр", – дип әйтәчәкбез»** («ән-Нәмел», 49).

Салих пәйгамбәргә кяферләрнең бу хәйләсе турында хәбәр ителә. Һәм ул гаиләсен, мөэминнәрне үзе белән алып, шәһәрдән чыгып китә. Шул рәвешле аятьтә хәбәр ителгән күченү вакыйгасы да чынга аша.

Тугыз кешелек азгыннар бандасы, ниятләрен тормышка ашыру өчен, төнлә Салих галәйһиссәләмнең өен камап ала. Өй эчендә һичкемне таба алмагач, аптыраушта калалар. Шуннан соң Җәбраил галәйһиссәләм, Аллаһның әмерен үтәп, аларны ташлар белән үтерә. Җәнабел-Хак:

وَمَكَرُوا مَكْرًا وَمَكَرْنَا مَكْرًا وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ

**«Алар хәйлә белән тозак кордылар, Без аларга шул мәкерлекләренең җәзасын ирештердек, әмма алар белмәделәр дә!»** – дип аңлата («ән-Нәмел», 50).

فَأَخَذَتْهُمُ الرَّجْفَةُ فَأَصْبَحُوا فِي دَارِهِمْ جَاثِمِينَ

**«(Аллаһның газабы аларны эләктерде). Аларны каты тетрәү тотты һәм алар өйләрендә җиргә капланып калганнарга әверелделәр»** («әл-Әгъраф», 78).

Аллаһ динен инкяр иткән һәм туры юлдан язган күпме кеше булса, барысы да һәлак ителә. Шәһәр хәрабәгә әйләнә.

Салих галәйһиссәләм һәм, иман китереп, аңа иярүчеләр (якынча дүрт мең кеше) ул шәһәрдән чыгып китә. Аяти кәримәләрдә бу хакта искә алына:

فَلَمَّا جَاءَ أَمْرُنَا نَجَّيْنَا صَالِحًا وَالَّذِينَ آمَنُوا مَعَهُ بِرَحْمَةٍ مِنَّا
وَمِنْ خِزْيِ يَوْمِئِذٍ إِنَّ رَبَّكَ هُوَ الْقَوِيُّ الْعَزِيزُ

**«Әмеребез килгәч, Салихны һәм аның янындагы иман китергән кешеләрне рәхмәтебез белән** (ул көннең газабыннан) **коткардык. Ул көннең хурлыгыннан да. Һичшиксез, синең Раббың – Иң көчле, Бөек»** («Һуд», 66).

وَأَنْجَيْنَا الَّذِينَ آمَنُوا وَكَانُوا يَتَّقُونَ

**«Без иман китергән һәм тәкъва булган кешеләрне** (илаһи газаптан) **коткардык»** («ән-Нәмел», 53).

Мөэминнәр шәһәрне калдырып киткәч, икенче көнне кяферләрнең йөзләре кып-кызыл төскә керә. Өченче көнгә исә кап-кара була. Алар, газап кайсы тарафтан килер икән, дип, курку һәм дәһшәт утында янып, як-якка карана. Хак Тәгалә Җәбраил галәйһиссәләмгә аларның мактана-мактана төзегән һәм үзләре бик горурланган ныклы биналарын пыран-заран китерергә куша. Залим кавемнең өйләре мизгел эчендә җир белән тигезләнә. Аяти кәримәдә бу хакта анык әйтелә:

فَتِلْكَ بُيُوتُهُمْ خَاوِيَةً بِمَا ظَلَمُوا إِنَّ فِي ذَلِكَ لَآيَةً لِّقَوْمٍ يَعْلَمُونَ

**«Аларның золымнары сәбәпле, җимерелеп, асты өскә килгән өйләре. Һичшиксез, монда белгән кешеләр өчен бер аять (гыйбрәт) бар»** («ән-Нәмел», 52).

Сәмуд кавеменә шундый бер куркыныч тавыш килә, Фәхреддин Разый сүзләре белән әйткәндә, бу куркыныч тавышның дәһшәтеннән һәркемнең үте шартлый һәм ул кешеләр һәлак була. Сәмуд халкының бу хәле төрле аятьләрдә бәян ителә:

فَأَخَذَتْهُمُ الصَّيْحَةُ بِالْحَقِّ فَجَعَلْنَاهُمْ غُثَاءً فَبُعْدًا لِلْقَوْمِ الظَّالِمِينَ

**«Куркыныч һәм көчле тавыш аларны бер гаделлек белән тотты да, шулай итеп, Без аларны аккан чүп шикелле иттек. Юк булсыннар залимнәр!»** («әл-Мүэминүн», 41).

وَأَخَذَ الَّذِينَ ظَلَمُوا الصَّيْحَةُ فَأَصْبَحُوا فِي دِيَارِهِمْ جَاثِمِينَ

**«Золым иткән кешеләрне исә тавыш тотты, һәм алар йортларында йөзтүбән капланган булдылар»** («Һуд», 67).

Сәмуд кавеме мал-мөлкәтләренә, байлыкларына һәм ныклы итеп төзегән биналарына ышанып, үзләрен котылып калырбыз дип саный. Ләкин илаһи каһәр чынга ашкач, йортларыннан бернинди дә файда күрә алмыйлар:

فَأَخَذَتْهُمُ الصَّيْحَةُ مُصْبِحِينَ. فَمَا أَغْنَى عَنْهُمْ مَا كَانُوا يَكْسِبُونَ

**«Дәһшәтле тавыш аларны таң вакытында каплады. (Һәм) ирешкән нәрсәләре алардан (газапны) ераклаштырмады»** («әл-Хиҗер», 83–84).

Сәмуд кавеме үзләренә хәтле һәлак ителгән халыкларның язмышыннан тиешле сабакны ала алмаганга күрә, үзләреннән соң яшәячәк кавемнәргә гыйбрәт үрнәгенә әйләнделәр:

فَأَخَذَهُمُ الْعَذَابُ إِنَّ فِي ذَلِكَ لَآيَةً وَمَا كَانَ أَكْثَرُهُمْ مُؤْمِنِينَ. وَإِنَّ رَبَّكَ لَهُوَ الْعَزِيزُ الرَّحِيمُ

**«(Шуннан соң) газап аларны тотты. Һичшиксез, монда бер билге (гыйбрәт) бар. Әмма аларның күбесе ышанган кемсәләр булмады. Һичшиксез, синең Раббың Бөек, Рәхимле (киң мәрхәмәт иясе)»** («әш-Шугара», 158–159).

Тәфсирләрдә әйтелгәнчә, бер төркем кавемнәр куркыныч тавыш ярдәмендә һәлак ителгән. Салих галәйһиссәләмнең кавеме Сәмуд – шуларның берсе. Алар җир астыннан килгән дәһшәтле аваз белән илаһи каһәргә дучар ителә. Мондый җәзага тарыган икенче халык – Шөгаеб галәйһиссәләм кавеме. Алары исә өстән килгән куркыныч тавыш белән юкка чыгарыла. Тагын бер кавем, «Йәсин» сүрәсендә искә алынганча, пәйгамбәрләренә иман китермәгән Әсхәбе Карья була.

Коръәни-Кәримдә кыямәтнең дә «Сайхатән ваһидәтән (бердәнбер куркыныч тавыш)» белән кубачагы белдерелә. Димәк, югарыда искә алынган кавемнәрнең һәлакәте үзенә күрә кыямәт күренешен хәтерләтә.

Салих галәйһиссәләм, кавеме һәлак ителгәч, үзенә ышанганнарга мондый киңәш бирә: «И, кавемем! Шик юк, бу – Аллаһ халыкка газап җибәргән җир. Моннан хәзер үк күченеп китегез һәм Аллаһның Хәраменә барып, иминлектә яшәгез».

Шуннан соң илаһи газаптан котылып калган мөэминнәр ихрамга керә дә, кызыл йонлы дөяләрне йөгәнләп, юлга кузгалалар. Тәлбия әйтә-әйтә, алар Мәккәгә барып җитә.

Күпмедер вакыттан соң мөэминнәр, хәрабәгә әйләнгән үз шәһәрләренә кире килеп, азгынлык һәм Аллаһ динен инкяр итүнең коточкыч нәтиҗәсен үз күзләре белән күрәләр. Мөэмин булганнары өчен, Аллаһка шөкер итәләр. Хәзрәти Салих галәйһиссәләм мөэминнәр белән бергә кабат үзләре һиҗрәт кылган шәһәргә (Мәккәгә) кайта. Гомерләрнең соңгы мизгеленә кадәр, алар шунда яши.

**Сәмуд кавеменең юк ителү сәбәпләре**

1. Көферлектә үҗәтлек күрсәттеләр һәм пәйгамбәрләрен мыскыллыдылар.

2. Тәкәбберләнделәр һәм азгын нәфесләренә иярделәр.

3. Үз караш-фикерләрен дин хөкемнәреннән өстен куйдылар. Шул рәвешле пәйгамбәрләренең дәгъватына колак салмадылар.

4. Нәсыйхәтләрне ишетмәделәр, тыңламадылар.

5. Дөяне үтергән тугыз явыз бәндә белән бергә булдылар.

6. Вәсвәсәче, котыртучы хатыннарның сүзен үтәделәр. Кытар белән Мыста Үнәйза һәм Мөхәййа кушканнарны эшләде. Ара бозучы бу хатыннарга күңел бирүләре аларны юлдан яздырды.

7. Хәерле, игелекле кешеләрне күралмадылар. Салих галәйһиссәләмне: «Син пәйгамбәр булганчы, башыбызга мондый бәлаләр килми иде!» – дип гаепләделәр.

8. Дөнья малына алдандылар.

9. Антларын боздылар, чөнки дөя могҗизасын таләп итеп, иманга киләчәкләре турында сүз биргәннәр иде.

10. Әманәткә хәянәт иттеләр. Аллаһның олуг әманәте булган дөяне, ант бирүләренә карамастан, үтерделәр.

11. Явыз, залим бәндәләр кылган гөнаһка риза булып тордылар. Дөяне тугыз кеше үтерде, ләкин башкалар моңа комачауларга тырышмады.

12. Дөя һичкемнең шәхси малы булмый, аны вакыф, җәмәгать малы, дияргә мөмкин. Сөтен исә хәер итеп таратыла торган су белән чагыштырырга була. Иясе – Җәнабел-Хак була. Ләкин Сәмуд халкы, дөяне үтереп, бик зур хыянәт ясады.

13. Тугыз кешенең явызлыгы чик-чаманы белми. Башкаларның малларын талап алдылар, бәндә хакына керделәр. Алар явызлык учагына, залимлек чыганагына әйләнгән була.

# КАВЕМНӘРНЕҢ ҺӘЛАК ИТЕЛҮЕ

Шактый җитди уяулык таләп иткән бу сынау дөньясында, ни кызганыч, күпчелек кешеләр тирән ваемсызлык йокысына чумган килеш яши. Әмма бу наданлык, юлдан язу, ваемсызлык йокысы аларны газаплы һәм кайгылы язмышка илтә. Дөнья алар өчен алдану мәйданына әйләнә.

Һәр тормыш юлы, начар узылганмы ул, яхшымы – кабергә бара. Тышкы яктан ялтыраган бу дөньяда имансызлыкның төп сәбәпләре – фикерләмәү, наданлык, ваемсызлык, шәһвәт, дөнья нигъмәтләренә чуму, гафилләргә иярү, чиктән тыш материалистик караштa тору, әхлаксызлык һәм шуның нәтиҗәсендә йөрәкне нәфескә корбан итү.

Кешелек тарихы иман һәм әдәп юлыннан тайпылган азгыннарның илаһи газапка тотылуына ничәмә-ничә тапкыр шаһит була. Нух, Гад һәм Сәмуд кавемнәренең тәкәббер бәндәләре; пәйгамбәрләргә каршы сугышкан, үзен алла дип игълан иткән һәм бер уч суда батып үлгән Фиргавен; бер чебен харап иткән Нәмруд; яшәешләре хәтта хайваннардан да түбәнрәк булган, бозык Лут кавеме һәм шуларга охшаш башкалар бу дөньядан үз золымнарын һәм баш-бирмәслекләрен кәфен итеп төренеп киттеләр.

Аллаһ Тәгалә андыйлар турында болай ди:

أَلَمْ يَأْتِهِمْ نَبَأُ الَّذِينَ مِنْ قَبْلِهِمْ قَوْمِ نُوحٍ وَعَادٍ وَثَمُودَ وَقَوْمِ إِبْرَهِيمَ وَأَصْحَابِ مَدْيَنَ وَالْمُؤْتَفِكَاتِ أَتَتْهُمْ رُسُلُهُم بِالْبَيِّنَاتِ فَمَا كَانَ اللهُ لِيَظْلِمَهُمْ وَلَكِنْ كَانُوا أَنْفُسَهُمْ يَظْلِمُونَ

**«Аларга үзләреннән әүвәлгеләр – Нух, Гад һәм Сәмуд кавеме, Ибраһим кавеме, Мәдйән халкының һәм асты өскә китерелгәннәр турында хәбәр ирешмәдеме? Рәсүлләр боларга ап-ачык могҗизалар алып килде. Аллаһ аларга гаделсезлек кылмады, ләкин алар үз-үзләренә золым иттеләр»** («әт-Тәүбә», 70).

Кяферлек, буйсынмаучанлык, золым һәм хаксызлык тарихында илаһи нәфрәт мисаллары бик күп. Аллаһка һәм пәйгамбәрләр күрсәткән юлга ризасызлык белдерүчеләр һәм каршы килүчеләрнең иртәме-соңмы Аллаһ кодрәте белән авыр җәза-газапка тарыячагы – һич котылгысыз һәм үзгәртелми торган илаһи канун ул.

Аллаһ Тәгалә пәйгамбәрләрне җәмгыятьтә нәфес теләкләре тарафыннан ачылган яраларга шифа рәвешендә кешеләргә тәкъдим итә. Ләкин дөньяның ялтыравыгына алданган бәндәләр исә пәйгамбәрләр ачкан нурлы офыклардан

читләшә, җәмгыятьләрен мәңгелек бәхетсезлекне хәтерләтеп торган куркыныч хәрабәләргә әйләндерәләр. Үзләренең рухи фәкыйрьлекләрен бәхет дип уйлап, алар бәлагә тарый, яратылуның хикмәтен һәм серен аңламыйча, хайвани яшәү рәвешен үз итәләр һәм, нәтиҗәдә, илаһи газапка дучар ителеп, һәлак булалар.

Коръәни-Кәримдә болай дип әйтелә:

وَكَمْ أَهْلَكْنَا قَبْلَهُمْ مِنْ قَرْنٍ هَلْ تُحِسُّ مِنْهُمْ مِنْ أَحَدٍ أَوْ تَسْمَعُ لَهُمْ رِكْزًا

**«Без алардан әүвәл ничәмә-ничә буыннарны һәлак иткән идек! Син алардан берәрсен таба аласыңмы? Яки аларның пышылдавын булса да ишетә аласыңмы?»** («Мәрьям», 98).

أَوَلَمْ يَسِيرُوا فِي الْأَرْضِ فَيَنْظُرُوا كَيْفَ كَانَ عَاقِبَةُ الَّذِينَ مِنْ قَبْلِهِمْ
كَانُوا أَشَدَّ مِنْهُمْ قُوَّةً وَأَثَارُوا الْأَرْضَ وَعَمَرُوهَا أَكْثَرَ مِمَّا عَمَرُوهَا وَجَاءَتْهُمْ
رُسُلُهُم بِالْبَيِّنَاتِ فَمَا كَانَ اللَّهُ لِيَظْلِمَهُمْ وَلَكِنْ كَانُوا أَنْفُسَهُمْ يَظْلِمُونَ

**«Алар җирдә һич гизмәделәрме, үзләреннән алда булган кешеләрнең ахырларының нинди икәнлеген күрмәделәрме? Алар көч ягыннан болардан куәтлерәк иде. Туфракны астын өскә китерделәр һәм алар аны боларның төзегәннәреннән күбрәк төзеделәр. Рәсүлләре дә аларга ап-ачык могҗизалар (күпме ачык дәлилләр) китергән иде. Аллаһ аларга золым итмәде, ләкин алар үз-үзләренә золым иттеләр»** («әр-Рум», 9).

Әлеге аятьләрдә су һәм төрле файдалы казылмалар чыгарган, иген үстерү өчен җир эшкәрткән, гаҗәеп шәһәрләр төзегән, соңыннан Аллаһны кире кагу аркасында аның газабына дучар ителгән Гад һәм Сәмуд кебек борынгы кавемнәргә ишарәләнә, аларның калдыкларына, хәрабәләренә карап, гыйбрәт алу кирәклеге искә төшерелә.

Кешедә «ачыгу» хисенең барлыкка килүе организм өчен кирәкле матдәләргә ихтыяҗ туу белән бәйле. Авырлык, кытлык чорларында кешеләрнең Аллаһта сыену эзләве исә җан ихтыяҗыннан килә. Хәзрәти Ибраһим утка ыргытылгач, утның пәйгамбәрне яндырмавын күреп, Нәмрудның: «Үземнең тәңречелегемнән баш тартмыйм, ләкин синең Раббың өчен дүрт мең сыер суйдырачакмын», – дип әйтүендә; суда һәлак булачагын аңлаган мизгелдә Фиргавеннең: «Бәни Исраил ышанган Аллаһка мин дә ышандым!» – дип әйтүендә бернинди дә файда юк. Башы бәлагә тарыган ваемсызларның, үлем куркынычы белән очрашкан кяферләрнең яклаучысыз-саклаучысыз калган аяныч мизгелләрдә аңга килүләре, күңел дөньясына игътибар юнәлтүләре кеше табигатендә дини ихтыяҗ таләбе булып тора.

Гомерләрен көферлек һәм ваемсызлык дулкыннарында тирбәлеп уздырган бәндәләрнең соңгы сәгатьләрдәге үкенечләре аяныч бәргәләнү һәм өметсезлекне чагылдыра. Үлем фәрештәсенең: «Моңарчы кайда идең соң син?» – дигән сүзләре искиткеч авыр газапның башлану мизгелен белдерә.

Үлем дөньяга караган бөтен зәвыкларны, ләззәтләрне юкка чыгара, шул ук вакытта барлык фани омтылышларга чик куя. Шуңа күрә изге бәндәләр, Аллаһны тиешле дәрәҗәдә таныганнар һәр сулышларын Хак Тәгаләне тәсбихкә әйләндереп, илаһи хакыйкатькә якынаялар. Алар тәннәрен һәркем өчен уртак үлем сынавы белән нурга күмеп, фанилыктан коткара. Кемнәрдер төрле җирләрдә, төрле йокы халәтендә булган чакта, алар бөтенләй башка төрле хәлгә керә.

Әгәр үлемнән качу һәм курку тиеш икән, кич җиткән саен куркып калтырануыбыз шарт. Ләкин төнге серләр дөньясына чумганда, күңелебездә курку тоймыйбыз, чөнки төннән соң таң атуның бер илаһи кагыйдә, табигый канун икәнен беләбез. Димәк, үлем кочагыннан да ниндидер хакыйкать таңының атачагын табигый кабул итүебез зарур.

Хак Тәгалә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّ وَعْدَ اللهِ حَقٌّ فَلَا تَغُرَّنَّكُمُ الْحَيَاةُ الدُّنْيَا وَلَا يَغُرَّنَّكُم بِاللهِ الْغَرُورُ

**«И, кешеләр! Һичшиксез, Аллаһның вәгъдәсе бер хак. Дөнья тормышы сине алдамасын. Алдакчы булган (шайтан) да сезне Аллаһ (ярлыкавы) белән алдамасын!»** – дип боера («Фатыйр», 5).

Бар галәм киңлеген колачларга маташып, ахирәтне оныткан, дөнья бизәкләренә алданган һәм фани ләззәтләргә чума-чума арыган бәндәләрнең ахыр язмышы никадәр газаплы һәм аяныч! Ислам дине исә җиһанга хикмәт күзлегеннән карарга боера һәм гомерне хак, тугры юлдан барып, аңлы рәвештә кичерергә куша. Җәнабел-Хак әйтә:

أَفَحَسِبْتُمْ أَنَّمَا خَلَقْنَاكُمْ عَبَثًا وَأَنَّكُمْ إِلَيْنَا لَا تُرْجَعُونَ. فَتَعَالَى
اللهُ الْمَلِكُ الْحَقُّ لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ رَبُّ الْعَرْشِ الْكَرِيمِ

**«Сез Без сезне күңел ачар (тиктомал гына) өчен яралттык һәм сез Безгә кайтарылмаячаксыз, дип санадыгызмы әллә? Хак падишаһ булган Аллаһ – өстен. Аннан башка һичбер илаһ юк, Ул – хөрмәтле Гарешнең Раббысы»** («әл-Мүэминүн», 115–116).

أَحَسِبَ النَّاسُ أَنْ يُتْرَكُوا أَنْ يَقُولُوا آمَنَّا وَهُمْ لَا يُفْتَنُونَ. وَلَقَدْ
فَتَنَّا الَّذِينَ مِنْ قَبْلِهِمْ فَلَيَعْلَمَنَّ اللهُ الَّذِينَ صَدَقُوا وَلَيَعْلَمَنَّ الْكَاذِبِينَ.
أَمْ حَسِبَ الَّذِينَ يَعْمَلُونَ السَّيِّئَاتِ أَنْ يَسْبِقُونَا سَاءَ مَا يَحْكُمُونَ

**«Кешеләр, “Иман китердек!” дип әйткәннәре өчен, сыналмыйча калдырылачаклар, дип санадымы әллә? Без алардан әүвәлгеләрне дә сынаган идек. Аллаһ тугры булганнарны да ачык күрсәтер, ялганчыларны да ачык күрсәтер. Әллә начар нәрсәләр кылучылар Безне узачаклар (кача алачаклар), дип саныйлармы? Карар биргән нәрсәләре нинди яман (ялгыш)!»** («әл-Ганкәбут», 2–4).

Ислам дине кешенең бишектән кабергә кадәр гомерен тәртипкә салып, аны ахирәт галәме серләренә һәм яшерен хикмәтләргә әзерли. Кешенең бишек белән табут арасындагы бәйләнешне аңламыйча, табигатьтәге үз урынын һәм вазифасын тәгаенләмичә, соңыннан үзе дә илтеләчәк зиратка баруның хикмәтен һәм гыйбрәтен төшенмичә, тормышын максатсыз рәвештә уздыруы – бик зур хәсрәт! Мондый хәлне, үзеңнән соң авыр истәлек калдырып, үлем чоңгылында юкка чыгу, дип кенә атарга була.

Пәйгамбәрләрнең бәндәчел көч-куәте беткәч, аларга илаһи ярдәм килә, аларны кире кагучыларда исә Аллаһның нәфрәте һәм каһәре чынга аша. 950 еллык сабырлыктан соң Нух галәйһиссәләмнең дә түземлеге төкәнә, аның Аллаһка ялваруы аяти кәримәдә дә хәбәр ителә:

فَدَعَا رَبَّهُ أَنِّي مَغْلُوبٌ فَانْتَصِرْ

**«Ул Раббысына дога кылды: «(Йә, Раббы) Мин җиңелдем. Син миңа ярдәм ит (үчемне ал)!»** («әл-Камәр», 10).

Кеше тормышында иң куркыткан һәм илаһи кисәтү булып торган вакыйгалар – су басулар, давыллар, җир тетрәүләр, ачлык, яшенле кара болытлар, дошман яулары һәм йогышлы чирләр кебек илаһи газап чагылышы белән бәйле. Күбесенчә «табигать күренешләре» дип каралган мондый вакыйгаларның барышы гаять куркыныч һәм аларда бик күп хикмәтләр яшеренгән. Бу төрдәге афәтләр кешеләрнең Аллаһ хөкемнәренә каршы чыгуы һәм гөнаһларга чумуы сәбәпле барлыкка килә. Һәм илаһи тәртип тарафыннан билгеләнгән афәтләр әнә шул рәвешле чынга ашырыла.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү һич тә залим түгел (Алла сакласын). Ләкин бәндәләрнең бу афәтләрне үзләре теләп барлыкка китерүе хак. Аллаһ нәфрәтенең әнә шундый бик авыр бәла-казалар рәвешендә чынга ашуын илаһи хөкемнәргә һәм изге нәрсәләргә каршы чыгучыларның татыячагы котылгысыз.

Хәтта агачтагы бер яфракның да Аллаһ ихтыяры белән төшкәнлеге Коръәни-Кәримдә телгә алына. Югыйсә, илаһи тәртип булмаса, табигатьтә анархия хөкем сөрер иде. Барлык физик күренешләрнең асылында мең дә бер төрле сер яшеренгән. Бу серләр пәйгамбәрләргә һәм Аллаһны ихлас йөрәге белән таныганнарга гына ачыла.

Коръәни-Кәримдә кавемнәрнең һәлакәте һәм боларның сәбәпләре, хикмәтләре белән бәйле бик күп аяти кәримә бар. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһ Тәгаләгә явызлык, золым хас түгел һәм ул һичкайчан колларына карата хаксызлык кылмый. Золым һәм хаксызлык – кешегә хас сыйфатлар. Аяти кәримәдә:

إِنَّ اللَّهَ لَا يَظْلِمُ النَّاسَ شَيْئًا وَلَكِنَّ النَّاسَ أَنْفُسَهُمْ يَظْلِمُونَ

**«Һичшиксез, Аллаһ кешеләргә һич бернәрсә белән золым эшләми. Ләкин кешеләр үз-үзләренә золым итәләр»**, – дип әйтелә («Йунус», 44).

Чиксез мәрхәмәт, йомшаклык һәм сабырлык иясе булган Бөек Раббыбыз кешеләрнең золымнары чиктән ашканда, аларны бик кырыс җәзалап, моны гыйбрәт итеп күрсәтә:

إِنَّ أَخْذَهُ أَلِيمٌ شَدِيدٌ

**«...Һичшиксез, Аның җәзасы тилмерткеч, бик каты!»** («Һуд», 102).

Хәтта шундый итеп эләктереп алып җәзалый һәм һәлак итә ки, мондый газапка дучар булганнарның башка аякка басуына, савыктырылуына юл куелмас. Бу чынбарлык аяти кәримәләрдә түбәндәгечә искә алына:

وَحَرَامٌ عَلَى قَرْيَةٍ أَهْلَكْنَاهَا أَنَّهُمْ لَا يَرْجِعُونَ

**«Без һәлак иткән авылның кайтулары (кабат торгызылуы) – мөмкин булмаган нәрсә, (чөнки алар кире кайта алмаячак)»** («әл-Әнбия», 95).

أَلَمْ يَرَوْا كَمْ أَهْلَكْنَا قَبْلَهُمْ مِنَ الْقُرُونِ أَنَّهُمْ إِلَيْهِمْ لَا يَرْجِعُونَ

**«Алар (мөшрикләр) үзләреннән алда килеп киткән күпме гасырларны (нәселләрне) һәлак иткәнебезне һәм аларның кайтмаганын күрмиләрме әллә?»** («Йәсин», 31).

Коръәни-Кәрим үткәндәге кавемнәрнең һәлакәте турында сөйләгәндә, моның сәбәпләрен дә телгә ала һәм шул рәвешле бу кавемнәрдән соң яшәячәк нәселләрне кисәтә. Аллаһның нигъмәтләренә карата рәхмәтсез мөнәсәбәт, шөкер итәсе урында, мул нигъмәтләр аркасында тәкәбберләнү, золым һәм хаксызлык кылуда алдынгы булу кебек зур гөнаһлар мондый сәбәпләрнең иң беренчеләре санала. Бу мәсьәлә белән бәйле аяти кәримәләрдә болай диелә:

وَكَمْ أَهْلَكْنَا مِنْ قَرْيَةٍ بَطِرَتْ مَعِيشَتَهَا فَتِلْكَ مَسَاكِنُهُمْ لَمْ
تُسْكَنْ مِنْ بَعْدِهِمْ إِلَّا قَلِيلًا وَكُنَّا نَحْنُ الْوَارِثِينَ

**«Яшәү өчен кирәк булган малның кадерен белмәгән ничәмә-ничә шәһәрләрне һәлак иттек. Менә аларның тораклары ки, алардан соң бик азлардан тыш, (бу биналарда) торучы булмады. (Барысы өчен дә) мирасчылар Без булдык»** («әл-Касас», 58).

وَمَا كُنَّا مُهْلِكِي الْقُرَى إِلَّا وَأَهْلُهَا ظَالِمُونَ

**«...Без халкы залимнәр булмаган шәһәрләрне һәлак итмәдек»** («әл-Касас», 59).

فَكَأَيِّنْ مِنْ قَرْيَةٍ أَهْلَكْنَاهَا وَهِيَ ظَالِمَةٌ فَهِيَ خَاوِيَةٌ عَلَى عُرُوشِهَا وَبِئْرٍ مُعَطَّلَةٍ وَقَصْرٍ مَشِيدٍ

**«(Халыклары) залим булганнары өчен Без һәлак иткән түбәләре өстенә ауган ничәмә-ничә шәһәр (ил) бар! Ничәмә-ничә кулланылмаган кое һәм (буш, матур) биек сарай»** («әл-Хаҗ», 45).

Кешеләр өстенә килгән барлык дөнья бәла-казаларының һәм ахирәт газапларының аларның шәхсән үзләре кылганнар өчен җавап икәнлеген Аллаһ Тәгалә анык хәбәр итә:

ظَهَرَ الْفَسَادُ فِي الْبَرِّ وَالْبَحْرِ بِمَا كَسَبَتْ أَيْدِي النَّاسِ لِيُذِيقَهُم بَعْضَ الَّذِي عَمِلُوا لَعَلَّهُمْ يَرْجِعُونَ

**«Кылган нәрсәләрнең бер өлешен аларга татытыр өчен, кешеләрнең куллары казанган нәрсәләр (гөнаһлар) сәбәпле, корыда һәм диңгездә бозыклык барлыкка килде. Бәлки, алар (начар юлдан баш тартып, Хак Тәгаләгә) кайтырлар»** («әр-Рум», 41).

Аяти кәримәдән аңлашылганча, тәртипсезлек, таркаулык, хаос – табигатьтә булсынмы ул, җәмгыять шартларындамы – кешеләрнең үз куллары белән кылган гамәлләре аркасында килеп чыга. Болар барысы да ширек, әхлаксызлык, хаксызлык һәм нәфес теләкләренә иярү аркасында чиктән ашулар сәбәпле барлыкка килә. Аллаһ Тәгалә, тәүбә итеп, ширектән ваз кичсеннәр, хак дингә, дөрес, нык юлга кайтсыннар, дип, кылган гөнаһларның бер өлеше өчен җәзаны бу дөньяда ук татыта. Әгәр тәүбә итеп, туры юлга (сыйрати мөстакыймгә) кайтмасалар, җәзаларын тулысынча ахирәттә татыячаклар, асыл газапны шунда беләчәкләр. Башка бер аяти кәримәдә:

وَمَا أَصَابَكُمْ مِنْ مُصِيبَةٍ فَبِمَا كَسَبَتْ أَيْدِيكُمْ وَيَعْفُوا عَنْ كَثِيرٍ

**«Сезгә килгән һәр бәла – кулларыгыз казанган нәрсәләр сәбәпле. (Шул ук вакытта) Ул бик күбен гафу итә»**, – дип ачыклана («әш-Шура», 30).

Асылда, эшләгән гөнаһлары өчен бәндәләрнең җәзаларын Җәнабел-Хак күп очракта ахирәткә кичектереп тора. Коръәни-Кәримдә бу хакта:

وَلَوْ يُؤَاخِذُ اللّٰهُ النَّاسَ بِظُلْمِهِم مَّا تَرَكَ عَلَيْهَا مِنْ دَآبَّةٍ

**«Әгәр Аллаһ кешеләрне золымнары сәбәпле тотып алса, хәрәкәтләнә алган бер генә җан иясен дә җир йөзендә калдырмас иде...»** – дип әйтелә («ән-Нәхел», 61).

Кылган гөнаһларның бер өлеше өчен җавап рәвешендә килгән бу бәла-казалар, бәлки, кешеләр яхшырырлар, дигән илаһи кисәтү сыйфатына ия. Ләкин Аллаһ Тәгаләнең ихлас мөэминнәр турында хөкеме моннан бераз аерыла, чөнки мөэминнәргә килгән бәла-казалар һәм кыенлыклар аларның гыйбадәттәге кимчелекләренә, гөнаһларына һәм хаталарына кәффарәт (ярлыкау) булачак. Мәсәлән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

*«Арыганлык, дәвамлы авыру, кайгы-хәсрәт, борчу-кыенлыклардан башлап, аякка кадалган энәгә кадәр мөселманның башына төшкән һәрнәрсәне Аллаһ аның хаталарын ярлыкау өчен бер сәбәпкә әйләндерер»* (Бохари, «Мәрда», 1, 3; Мөслим, «Бирр», 49).

Аллаһ ризалыгы өчен тырышкан, хезмәт куйган берәр зат тарыган авырлыклар аның гөнаһларына кәффарәт булып кына калмыйча, шул ук вакытта аның Аллаһ катындагы дәрәҗәсен дә күтәрер.

Җәнабел-Хак һәлак ителгән кавемнәрнең кыйссаларын кыяматкәчә килеп китәчәк кешелек нәселен кисәтү, аларга бер гыйбрәт күрсәтү өчен кабат-кабат сөйләгәнлеген болай дип искә ала:

وَلَقَدْ أَهْلَكْنَا مَا حَوْلَكُمْ مِنَ الْقُرَى وَصَرَّفْنَا الْآيَاتِ لَعَلَّهُمْ يَرْجِعُونَ

**«Без сезнең тирә-ягыгызда булган шәһәрләрне һәлак иттек инде. Без бит алар (туры юлга) кайтсыннар, дип аятьләрне төрлечә кабатлаган идек!»** («әл-Әхкаф», 27).

وَلَقَدْ تَرَكْنَاهَا آيَةً فَهَلْ مِنْ مُدَّكِرٍ

**«Без аны (Нух көймәсен һәм туфан билгеләрен) бер билге (гыйбрәт) буларак калдырдык, ләкин үгет алучылар бармы?»** («әл-Камәр», 15).

وَكَمْ أَهْلَكْنَا قَبْلَهُمْ مِنْ قَرْنٍ هُمْ أَشَدُّ مِنْهُمْ بَطْشًا فَنَقَّبُوا فِي الْبِلَادِ هَلْ مِنْ مَحِيصٍ.
إِنَّ فِي ذٰلِكَ لَذِكْرَى لِمَنْ كَانَ لَهُ قَلْبٌ أَوْ أَلْقَى السَّمْعَ وَهُوَ شَهِيدٌ

**«Без алардан алда шәһәрләрдә ярыклар ярган (качарга тишек эзләгән) ничәмә-ничә буынны һәлак иттек. Алар бит көч ягыннан болардан куәтлерәк иде, ләкин (үлемнән) качу урыны бармы соң? Һичшиксез, боларда йөрәге булган яки үзе булып колак салган кешеләргә бер үгет (гыйбрәт) бар»** («Каф», 36–37).

أَفَلَمْ يَسِيرُوا فِي الْأَرْضِ فَتَكُونَ لَهُمْ قُلُوبٌ يَعْقِلُونَ بِهَا أَوْ آذَانٌ يَسْمَعُونَ بِهَا فَإِنَّهَا لَا تَعْمَى الْأَبْصَارُ وَلَكِنْ تَعْمَى الْقُلُوبُ الَّتِي فِي الصُّدُورِ

**«Аңлый ала торган йөрәкләре яки ишетә торган колаклары була торып, җирдә һич гизмәделәрме әллә? Һичшиксез, күзләр сукыр түгел, ләкин күкрәкләр эчендәге йөрәкләр сукыр!»** («әл-Хаҗ», 46).

Йөрәк бөтен хис-тойгылар белән бергә әхлак һәм акыл сыйфатларының үзәге дә буларак кабул ителгәнгә, аяти кәримәдә кирелекләре һәм кяферлектәге үзсүзлелекләре андый бәндәләргә хакыйкатьне ишетергә һәм акыл белән эш йөртергә комачаулаганы белдерелә.

Раббыбыз – Нәмрудның утларын Хәзрәти Ибраһимнең иманы бәрабәренә гөлбакчага әйләндергән, Фиргавен хакимлеген Хәзрәти Мусаның таягы белән җимерткән, Кәгъбәне ишәргә маташкан Әбрәһә армиясенең филләрен һәм солдатларын вак-вак кошлардан талатып, Мәккә тирәсен фил каберлегенә әйләндергән, башка шуларга охшаган азгын кавемнәрне пыран-заран китергән, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне «фәрештә, җил, курку» кебек күзгә күренмәс гаскәрләр белән куәтләндереп, Аңа җиңү юлларын ачкан кодрәт иясе.

Гөнаһлы кавемнәрне юк итү урыннары үзләре дучар булган һәлакәтнең эзләрен һәм тәэсирләрен кыяматкәчә саклаячак. Хушлашу хаҗы вакытында Мина белән Мөздәлифә арасындагы Мөхассар үзәнлеген узганда, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм адымын тизәйтә. Янында булган әсхәбе кирам:

«Йә, Рәсүлүллаһ, ни булды, ник тизәйдегез?» – дип сорагач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип җавап бирә:

*«Бу урында Җәнабел-Хак Әбрәһә армиясен юк итте. Ул һәлакәтнең бер өлеше килмәсен өчен, тизрәк атладым!»*[64]

Шуңа күрә хаҗ вакытында бу урында тукталыш ясалмый.

Тәбүк походы вакытында әсхәбе кирам Сәмуд кавеме һәлак ителгән җирдән үткәндә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Таштан уелган бу йортларга кайгылы йөз белән керегез! Моннан бернәрсә дә алмагыз! Чөнки монда юлдан язган кавемгә илаһи газап килде...»* – дип әйтә.

Сәхабәләр:

«Йә, Рәсүлүллаһ, турсыкларыбызга су тутырдык. Хәтта шул су белән камыр бастык!» – диләр.

64. Карагыз: Мөслим, «Хаҗ», 147; Нәвәви, «Шәрху Сахихи Муслим», VIII, 190; Гали әл-Кариъ, «Миркатүл-Мәфатих», V, 1774–1775.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Суларыгызны бушатыгыз, камырларыгызны ташлагыз!»* – дип боера (Бохари, «Әнбия», 17).

Илаһи ачу чынга ашырылган авыл-калаларда, гөнаһ һәм кяферлек белән тулы урыннарда сакланып калган ул каһәрнең тәэсиренә эләкмәс өчен, бу урыннарда тукталмаска кирәк, үтеп китәргә туры килгәндә исә тиз-тиз узып китү зарур.

Кәгъбә, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм башка пәйгамбәрләрнең шәрәфле каберләре, мәчетләр, изге, тугры затлар яшәгән урыннар исә гыйлем, фазыйләт тупланган җирләр санала, шуңа күрә монда күңелебезгә бәрәкәтле рәхмәт һәм фазыйләт яңгырлары явар.

Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмнән башлап, кешеләрне алар баткан имансызлык һәм әхлаксызлык караңгылыгыннан коткару өчен, Аллаһ вакыт-вакыт пәйгамбәрләр җибәргән һәм китаплар иңдергән. Бу – Раббыбызның бик зур рәхмәте һәм нигъмәте. Ахырда исә кешелекнең мәңгелек юламаны – соңгы пәйгамбәр Хәзрәти Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм килә. Шулчакта чүлгә төшкән илаһи нур үз күләгәсенә мәңгелекне колачлый.

Ислам дине кешене җитдилеккә өнди һәм, иртәгә Аллаһ хозурына басып, үзе яшәгән гомер өчен хисап тотачагын кат-кат искә төшереп тора. Шул сәбәпле мөэмин, буш, файдасыз эшләргә вакыт биреп, гайбәт сөйләп, кирәксез сораулар биреп, дини һәм әхлакый абруен төшерерлек гамәлләр кылмаска тиеш. Наданнардан ерак тору, кирәкмәс маҗаралар артыннан йөрмәү, төрле юләрлекләргә, әшәкелекләргә, азгынлыкларга һәм максатсыз эш-гамәлләргә кереп китмәү зарур. Хак юлдан тайпылдыра торган фәлсәфәләрнең чыгар тишеге булмаган урамнарында бөтенләй йөрмәскә кирәк.

Җәйге болыт кебек килеп киткән дөнья тормышын ахирәт өчен борчылмыйча уздыру – якты көннең киче булмас, дип кабул итү кебек үк мантыйксыз гамәл. Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ болай дип яза:

«Тәнне артык ашатып, тукландырып үстерергә тырышма! Чөнки ул ахырда туфракка бирелә торган бер корбан гына. Син күңелеңне гыйлем чишмәләреннән тутырырга омтыл. Югарыга китеп, хөрмәткә лаек булачагы әнә шул.

Җәсәдеңә майлы-татлы нәрсәләрне аз бир, чөнки тәнен артык ашатучы нәфес теләкләренә чума һәм ахырда исә оят-хурлыкка калып китә.

Жаныңа рухи ризыклар бир. Өлгергән фикерләү сәләте, нәфис аң-зиһен, рухи азык тәкъдим ит, барачак җиренә көч-куәтле булып китсен!»

Раббыбыз һәрбарчабызны хәсрәт-казаларга тарудан саклый күрсен. Барыбызга да нәгыйм җәннәтләренә керергә насыйп итсен!

Амин!..

***Хәзрәти Салих галәйһиссәләм***





ХӘЗРӘТИ

# ИБРАҺИМ

*галәйһиссәләм*

### *Нәмрудның золымына һәм янауларына бирешмәгән, ут өемнәрен гөлбакчаларга әйләндергән*

# ХӘЗРӘТИ ИБРАҺИМ

### *галәйһиссәләм*

Хәзрәти Ибраһим Вавилонның көнчыгышында, Тигр һәм Евфрат елгалары арасындагы өлкәдә дөньяга килә. Бер риваятькә күрә, атасы Тарух ихлас мөэмин була. Тарух бакыйлыкка күчкәч, Ибраһим галәйһиссәләмнең анасы Тарухның бертуганы Азәргә кияүгә чыга. Потларга табынган Азәр шул рәвешле Ибраһимнең үги атасына әйләнә. Башка бер риваятьтә исә Тарух Ибраһим галәйһиссәләм атасының элекке исеме дип әйтелә. Потларга табына башлагач, исеме Азәр дип үзгәртелә. Имам Суюти рәхмәтуллаһи галәйһи, Ибне Габбастан килгән бер риваятькә нигезләнеп, Азәр Ибраһим галәйһиссәләмнең атасы түгел, ә атасының бертуганы дип белдерә.

Ибраһим галәйһиссәләм Кәлдани кавеменә җибәрелә. Рәсүлүллаһ саллəллаһу галәйһи вә сәлләмнән соң кешеләрнең иң фазыйләтлесе санала. Хак Тәгалә аны «Хәлилем» (Дустым) дип олылаган. Шунлыктан Ибраһим галәйһиссәләм «ХәлилүрРахман» исеме белән дә искә алына.[65]

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләмгә ун сәхифә иңдерелә. Әбу Зәр радыйаллаһу ганһе Аллаһ Рәсүле саллəллаһу галәйһи вә сәлләмнән тапшырган риваятькә күрә, бу сәхифәләрдә түбәндәге үгет-нәсыйхәтләр һәм гыйбрәтле киңәшләр язылган була:

*«Әй, хакимлек бирелеп, сынау узучы һәм алданучы король! Мин сине бар дөньяны бер урынга өйсен, дип җибәрмәдем. Мескеннәрнең догасын Миннән алырсың, кыерсытылганнарны Миңа ялварыр хәлдә калдырмассың, дип җибәрдем, чөнки Мин кыерсытылганнарның догасын, хәтта алар кяфер булса да, кире бормам».*

*«Акыл иясенең билгеле бер вакытлары булырга тиеш:*

*– Ул вакытының бер өлешен Раббысына дога һәм ялваруга;*

*– Бер өлешен Бөек Аллаһның осталыгы һәм кодрәте турында уйлануга;*

*– Бер өлешен үткәндә теләгәннәре һәм киләчәктә теләячәк нәрсәләре турында үз-үзенә хисап ясауга;*

65. Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләмнең олуг пәйгамбәрләрдән булуы, үзен Аллаһка багышлавы, Аңа тәвәккәл кылуы белән дастаннарда мактарлык дәрәҗәгә менүе, барыннан да бигрәк «Хәлилуллаһ – Аллаһның дусты» булуы сәбәпле, ислам җәмгыятендә бик зур мәхәббәт казана, моның табигый нәтиҗәсе буларак, бик күпләр улларына «Хәлил Ибраһим» исеме куша.

*– Бер өлешен исә хәләл юл белән тормышын тәэмин итүгә багышларга тиеш»* (Әбу Нугайм, «Хилья», I, 167; Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 124).

Хәзрәти Ибраһимнең тагын бер үзенчәлеге «Әбул-әнбия» (Пәйгамбәрләр атасы) булудан гыйбарәт. Уллары – Исмәгыйль галәйһиссәләм белән Исхак галәйһиссәләм. Исмәгыйль галәйһиссәләм нәселеннән – Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм; Исхак галәйһиссәләм нәселеннән исә Бәни Исраил пәйгамбәрләре дөньяга килә.

Хәзрәти Ибраһимнең исеме Коръәни-Кәримнең егерме биш сүрәсендә алтмыш тугыз тапкыр телгә алына. Коръәни-Кәримдә аны мактаган төрле исем-сыйфатларны да күрәбез. Бу сыйфатларның кайберләре:

Әүваһ (күп ялваручы);

Хәлим (түземлек иясе, йомшак холыклы);

Мөниб (Аллаһка ихлас күңел белән юнәлүче);

Хәниф (ширек һәм имансызлыктан ерак торып, тәүхид дингә нык ябышучы);

Канит (Аллаһка гыйбадәт кылучы);

Шакир (күп шөкер кылучы).

Ибраһим галәйһиссәләм яшәешен тәэмин итү максатында, тукыма һәм кием-салым белән сәүдә итә, һиҗрәттән соң терлекчелек белән шөгыльләнә.

Кәлдани кабиләсе башлыгы Нәмруд баштарак мәлдә гадел һәм инсафлы зат булып таныла. Аның кавеме йолдызларга һәм потларга табына. Соңыннан Нәмруд, хакимияте, дәүләте киңәйгәч, тәкәбберләнә һәм, һәйкәлләр ясатып, кавеменә: «Мин дә алла, миңа да табыныгыз!» – дип мөрәҗәгать итә.

Риваятьтә әйтелгәнчә, Нәмруд күктә бер нур ялтыраганын һәм аның кояш белән ай яктысын сүндергәнен беркөнне төшендә күрә. Башка риваятьтә исә, төшенә бер кешенең килеп, аны тәхеттән тартып төшереп, җиргә екканы керә. Йокыдан уянгач, Нәмруд бик дулкынлана. Йолдызларга карап гомерне фаразлаучы астрологларны сараена чакырып, ул төшен сөйләп бирә. Тегеләре: «Яңа дин киләчәк. Ул динне алып килгән зат синең тәхетеңне җир белән тигезләячәк. Аңа каршы чарасын күр!» – диләр.

Шуннан соң Нәмруд киңәшчеләре, бу фаразланган хәлгә комачаулау өчен, һәр туган ир баланы үтерергә карар чыгара. Әнә шул сәбәпле ул вакытларда яңа туган йөз мең чамасы бала үтерелә.

Шулчакта Ибраһим галәйһиссәләмнең анасы Ибраһим белән йөкле була. Бала табар вакыты якынайгач, ул ире Азәргә: «Син потханәгә барып, минем өчен дога кыл! Әгәр ир бала тапсам, сиңа алып килермен. Аны Нәмрудка илтеп бирерсең. Ул исә баланы үтерер. Шулай итеп, Нәмруд каршында синең дәрәҗәң күтәрелер», – ди.

Азәр потханәгә киткәч, Ибраһим галәйһиссәләм туа. Анасы аны яшереп кенә бер мәгарәгә урнаштыра. Азәр өйгә кайткач, аңа сабыйның бик зәгыйфь булып туганлыгын һәм шуңа күрә инде җан биргәнлеген әйтә.

Ибраһим галәйһиссәләмнең әнисе, Азәр өйдән чыгып китүгә, шундук баласы янына барып, аны имезә. Моннан соң да, төрлечә форсат табып, сабыен ашатырга барып йөри. Кайчак ул Хәзрәти Ибраһимнең бармакларын суырып ятканын күргәли. Чөнки Җәбраил галәйһиссәләм булачак пәйгамбәрнең бармаклары арасыннан май, бал, сөт һәм хөрмә йомшагы актыра.

Ибраһим галәйһиссәләмнең балачагы мәгарәдә узуы, мәгарәдән чыгуга тәүхид диненә чакыра башлавы риваятьтә сөйләнә.

Аяти кәримәдә:

وَلَقَدْ آتَيْنَا إِبْرَهِيمَ رُشْدَهُ مِنْ قَبْلُ

**«Без Ибраһимгә моңа кадәр рүшдне (хак юлны) биргән идек...»** – дип әйтелә («әл-Әнбия», 51).

«Рүшд» сүзе хәерле, дөрес юлны табу, турыны кәкредән аеру, Аллаһ юлында нык һәм сабыр булу, анык юнәлеш белән туп-туры бару дигәнне белдерә.

Ибраһим галәйһиссәләм: «Аллаһтан башка илаһ юк, Ул – минем Раббым, Ул – һәрнәрсәнең Раббысы», – дигәч, ата-анасы Нәмрудтан куркып елый һәм Ибраһимне кисәтеп куярга тырышалар. Аларның бу борчылуларына карата Хәзрәти Ибраһим:

«Минем өчен Нәмрудтан бөтенләй курыкмагыз. Мине нәни вакытымда саклаган Аллаһ Тәгалә инде үсеп җиткәч тә саклар», – дип белдерә (Ибне Ияс, «Бәдайигуз-Зуһур», 84 б.).

### Раббым – Аллаһ

Азәр пот ясап та һәм тормышын шуның белән алып бара. Азәрнең башка уллары да мактый-мактый пот сату белән шөгыльләнә. Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм исә сатар өчен аңа Азәр биргән потны, муенына бау белән асып, базарга алып килә дә:

«Ни зыяны, ни файдасы булган бу потларны алучы кеше бармы?» – дип, көлкеле рәвештә кычкырып тора, аннан пот сатып алучы табылмый. «Шул кирәк сиңа», дигәндәй, ул потларны, кимсетеп, җирдән сөйрәп йөри. Аннары:

«Бик сусадың, бераз син дә эчеп ал!» – дип, потның башын суга тыга.[66]

66. Карагыз: Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 96; Табәри, «Тарих», I, 237; Саләби, «Араис», 75 б.

Ибраһим галәйһиссәләм Аллаһ тарафыннан бирелгән туры юл бәрабәренә һичкемнең тәрбиясен, дәрес-сабакларын алмыйча, күпме бөек илаһи хакыйкатьләрнең белгеченә һәм тәүхид юлын күрсәтүчегә әйләнә. Аның яшь чакларында ук Раббысын тануы һәм кавемен дә шуңа өндәве аяти кәримәләрдә болай сурәтләнә:

فَلَمَّا جَنَّ عَلَيْهِ اللَّيْلُ رَأَى كَوْكَبًا قَالَ هَـذَا رَبِّي فَلَمَّا أَفَلَ قَالَ لَا أُحِبُّ الآفِلِينَ. فَلَمَّا رَأَى الْقَمَرَ بَازِغًا قَالَ هَـذَا رَبِّي فَلَمَّا أَفَلَ قَالَ لَئِنْ لَمْ يَهْدِنِي رَبِّي لَأَكُونَنَّ مِنَ الْقَوْمِ الضَّالِّينَ. فَلَمَّا رَأَى الشَّمْسَ بَازِغَةً قَالَ هَـذَا رَبِّي هَـذَا أَكْبَرُ فَلَمَّا أَفَلَتْ قَالَ يَا قَوْمِ إِنِّي بَرِيءٌ مِمَّا تُشْرِكُونَ. إِنِّي وَجَّهْتُ وَجْهِيَ لِلَّذِي فَطَرَ السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضَ حَنِيفًا وَمَا أَنَا مِنَ الْمُشْرِكِينَ

**«Төн аны каплагач, бер йолдыз күрде һәм: “Бу – минем Раббым”, – дип әйтте. Ул баткач исә: “Мин батканны сөймим”, – диде. (Аннары) Айны туып килгән чагында күргәч (янә): “Бу – минем Раббым”, – диде. Ул да баткач: “Раббым мине һидәяткә ирештермәсә, мин, һичшиксез, адашкан кавемнән булырмын”, – диде. Кояшны туып килгән чагында күргәч исә: “Бу – минем Раббым. (Чөнки) бу – иң зурысы”, – диде. Ул баткач, әйтте: “И, кавемем! Һичшиксез, мин сезнең (Аллаһка) ширек кушкан нәрсәләрегездән еракмын. Мин, хәниф[67] буларак, йөземне күкләрне һәм җирне юктан бар иткән Затка (Аллаһка) юнәлттем. Мин ширек кылучылардан түгелмен”»** («әл-Әнгам», 76–79).

Әлеге аяти кәримәләрдә белдерелгән хакыйкать Ибраһим галәйһиссәләмнең Аллаһтан башкага табынган мескеннәргә юлларының ялгыш, ышанган нәрсәләренең ялган икәнлеген күрсәтүеннән гыйбарәт. Әйтик, Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм бер йолдыз күргәч: «Бу минем Раббым булачак!» – ди. Әүвәл ул бер йолдызның Алла булырга мөмкин икәнен фаразлап, әйләнә-тирәсендәгеләргә әнә шундый читләтеп мөрәҗәгать итә. Озак та үтми ул йолдыз баткач: «Мин батканны сөймим», – дип, илаһка ышануда һәм гыйбадәт кылуда мәхәббәтнең иң төп нигез икәнлеген, бату, күздән югалу сыйфатының илаһлык түгел, ә яралтылу һәм юк ителү дәлиле икәнлеген белдерә.

67. «Хәниф» сүзе, хаталы, ялгыш диннәрдән, дөрес түгел фикерләрдән һәм начар әхлактан йөз чөереп, һәрдаим дөреслеккә, хәерлегә күңел биргән, мөселман булып, бары Аллаһ хөкемнәрен генә танып, Аллаһка ихлас гыйбадәт кылган, әҗер-савабын бары тик Аннан гына көткән затны белдерә. Әлеге сүз гакыйдә, әхлак һәм мөгамәлә ягыннан исламның аермалы үзенчәлеген күрсәтә. Хәнифлек Хәзрәти Ибраһим диненең һәм аның халкының сыйфаты булу белән бергә, боларга гына карамый, гомумән, потка табынуның бер антонимы буларак, хәнифлек бөтен пәйгамбәрләр җибәрелгән милләтләрнең һәм тәүхид диненең атамасы булып тора. Хәнифләр – асылда, бөтен ширек диннәргә каршы чыгып, бердәнбер Аллаһ диненә юнәлтү, бары Аллаһка гына гыйбадәт кылу өчен дәгъват һәм көрәш алып бару вазифасын башкарган пәйгамбәрләрнең диннәренә иярүче, ялганнан сакланып, Хак Тәгаләгә күңел биргән тәүхид әһле, мөселманнар ул.

Шул сәбәпле мондый нәрсәләрне илаһ дип уйлауның ахыры файдасыз, адашу булганын, Раббыны мәңгелек, яралтучы кодрәт иясе дип тану кирәклеген аңлата.

Бу үрнәк шулай ук гакылга ия һәркемнең үзен яралткан Аллаһның барлыгын һәм берлеген тану өчен кирәкле белемнәргә һәм иманга фикерләү аша ирешә алачагын да раслый. Шунлыктан әһле-сөннәт галимнәренең бер өлеше исламга өндәү, дәгъват күрмәгән кешеләрнең дә, хакыйкатькә, туры юлга басар өчен Аллаһның барлыгына һәм берлеген ышануда бурычлы икәнлеген, ләкин гыйбадәт гамәлләрен башкару мәсьәләсендә җавапка тартылмаячакларын белдерә.

**Тәүхидкә өндәү**

Илаһи хакыйкатьләрне аңлап, Раббысын тапкан һәм үзенә Аллаһ тарафыннан һәркемгә дә бирелми торган гыйлем насыйп ителгән Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм, тәүхидкә өндәп, дәгъват кылу эшен атасы Азәрдән башлый. Аңа, йомшак мөгамәлә күрсәтеп, болай сүз ката:

إِذْ قَالَ لِأَبِيهِ يَا أَبَتِ لِمَ تَعْبُدُ مَا لَا يَسْمَعُ وَلَا يُبْصِرُ وَلَا يُغْنِي عَنْكَ شَيْئًا. يَا أَبَتِ إِنِّي قَدْ جَاءَنِي مِنَ الْعِلْمِ مَا لَمْ يَأْتِكَ فَاتَّبِعْنِي أَهْدِكَ صِرَاطًا سَوِيًّا. يَا أَبَتِ لَا تَعْبُدِ الشَّيْطَانَ إِنَّ الشَّيْطَانَ كَانَ لِلرَّحْمَنِ عَصِيًّا. يَا أَبَتِ إِنِّي أَخَافُ أَنْ يَمَسَّكَ عَذَابٌ مِنَ الرَّحْمَنِ فَتَكُونَ لِلشَّيْطَانِ وَلِيًّا

**«И, әтием! Ишетмәгән, күрмәгән һәм сине бернәрсәдән дә коткара алмаган нәрсәләргә ни өчен табынасың? И, әтием! Сиңа килмәгән гыйлем миңа килде. Син миңа ияр дә, мин сине туры юлга кертим. И, әтием! Шайтанга табынма. (Чөнки) шайтан – Рахманга каршы баш күтәрүче бит. И, әтием! Һичшиксез мин Рахманнан сиңа бер газап кагыласыннан һәм синең шайтанга якын булачагыңнан куркамын!»** («Мәрьям», 42–45).

Азәр исә кызып китә:

قَالَ أَرَاغِبٌ أَنْتَ عَنْ آلِهَتِي يَا إِبْرَاهِيمُ لَئِنْ لَمْ تَنْتَهِ لَأَرْجُمَنَّكَ وَاهْجُرْنِي مَلِيًّا

**«”Әй, Ибраһим! Әллә син минем илаһларымнан йөз чөерәсеңме? Әгәр (аларга тел тидерүдән) ваз кичмәсәң, һичшиксез, сиңа ташлар белән атармын. Мине озак вакытка калдыр (кит)!” – ди»** («Мәрьям», 46).

Ләкин Ибраһим галәйһиссәләм Азәргә янә каты бәрелмичә, ягымлы тел белән җавап бирә:

قَالَ سَلَامٌ عَلَيْكَ سَأَسْتَغْفِرُ لَكَ رَبِّي إِنَّهُ كَانَ بِي حَفِيًّا

**«(Ибраһим) әйтте: “Сәлам сиңа! Синең өчен Раббымнан ярлыкау сораячакмын. Ул миңа карата бик шәфкатьле булды”»** («Мәрьям», 47).

Шуннан соң ул әтисенең ярлыкануы өчен дога кыла. Әмма догасы кабул ителми, чөнки атасы Аллаһның дошманы була. Ибраһим галәйһиссәләм моны тәмам аңлагач, догадан шундук баш тарта. Чөнки кяферләрнең гафу ителүен түгел, ә аларның һидәяткә ирешүен сорап кына дога кылырга ярый. Коръәни-Кәрим бу мәсьәләне түбәндәгечә ачыклый:

مَا كَانَ لِلنَّبِيِّ وَالَّذِينَ آمَنُوا أَنْ يَسْتَغْفِرُوا لِلْمُشْرِكِينَ وَلَوْ كَانُوا أُولِي قُرْبَى مِنْ بَعْدِ
مَا تَبَيَّنَ لَهُمْ أَنَّهُمْ أَصْحَابُ الْجَحِيمِ. وَمَا كَانَ اسْتِغْفَارُ إِبْرَهِيمَ لأَبِيهِ إِلَّا عَنْ مَوْعِدَةٍ
وَعَدَهَا إِيَّاهُ فَلَمَّا تَبَيَّنَ لَهُ أَنَّهُ عَدُوٌّ لِلَّهِ تَبَرَّأَ مِنْهُ إِنَّ إِبْرَهِيمَ لَأَوَّاهٌ حَلِيمٌ

**«Аларның ут (җәһәннәм) ияләре булуы аларга белдерелгәннән соң, Пәйгамбәр дә, иман китерүчеләр дә, (Аллаһка) ширек кушкан кешеләр өчен ярлыкау сорарга тиеш түгел, хәтта алар туганнар булса да. Ибраһимнең атасы өчен истигъфары (исә) фәкать аңа вәгъдә иткән сүзендә тору гына иде. Ул аның Аллаһның дошманы икәнен аңлагач, аңардан (шундук) баш тартты. Һичшиксез, Ибраһим бик түбәнчелекле, йомшак иде»** («әт-Тәүбә», 113–114).

Ибраһим галәйһиссәләмнең атасы һәм кавеме белән көрәше, алар тоткан ширек юлның ялгышлыгын аңлатуы һәм аларны мантыйклы дәлилләр белән тәүхид иманга өндәве Коръәни-Кәримдә кабат-кабат искә алына. Мондый урыннарның берсендә Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләмнең иманга килмәгән атасы һәм кавеме белән түбәндәге әңгәмәсе бәян ителә:

إِذْ قَالَ لِأَبِيهِ وَقَوْمِهِ مَا هذِهِ التَّمَاثِيلُ الَّتِي أَنْتُمْ لَهَا عَاكِفُونَ. قَالُوا وَجَدْنَا آبَاءَنَا لَهَا عَابِدِينَ.
قَالَ لَقَدْ كُنْتُمْ أَنْتُمْ وَآبَاؤُكُمْ فِي ضَلَالٍ مُبِينٍ. قَالُوا أَجِئْتَنَا بِالْحَقِّ أَمْ أَنْتَ مِنَ اللَّاعِبِينَ.
قَالَ بَلْ رَبُّكُمْ رَبُّ السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ الَّذِي فَطَرَهُنَّ وَأَنَا عَلَى ذلِكُمْ مِنَ الشَّاهِدِينَ

**«Менә ул әтисенә һәм кавеменә: “Сез бик нык табынган бу сыннар нәрсәләр соң?” – диде. Алар: “Без аталарыбызны боларга табынган кемсәләр хәлендә таптык!” – диделәр. Ул (Ибраһим): “Сез һәм аталарыгыз ап-ачык бер адашу эчендә булдыгыз”, – диде. Алар (кавеме): “Син безгә хак белән килдеңме, әллә син уйныйсыңмы?” – диделәр. (Шуннан соң) ул (Ибраһим) әйтте: “Юк! Сезнең Раббыгыз – күкләрнең һәм җирнең Раббысы, Ул аларны юктан бар итте. Мин исә моңа шаһитлык итүчеләрдәнмен”»** («әл-Әнбия», 52–56).

**Хәзрәти Ибраһимнең потларны җимерүе**

Кәлдани кабиләсе, елның бер көнендә җыелып, бәйрәм уздыра торган була.

«Бүген бәйрәм ясар өчен син дә безнең белән бар!» – дип, Азәр Хәзрәти Ибраһимне дә дәшә. Юлда чакта, авыруын сылтау итеп, Ибраһим галәйһиссәләм кире кайта да потханәгә юнәлә. Анда көмеш, бакыр һәм агачтан ясалган потлар була. Алларына исә, бәрәкәт китерсен, дип, ризыклар да куелган. Иң зур пот исә алтын тәхет өстенә утыртылган. Аңа ялтыравык киемнәр кидереләп, башына таҗ куелган.

Ибраһим галәйһиссәләм зур поттан кала барысын да балта белән кискәләп чыга. Аннары балтаны зур потның муенына асып куя. Кич җиткәч, Кәлдани кабиләсе бәйрәм оештырылган урыныннан потханәгә кайта. Андагы манзараны күреп, бик нык аптырашта калалар.

«Моны шул Ибраһим генә эшли ала!» – дип гөманлый алар. Шуннан соң тизрәк Ибраһим галәйһиссәләмне эзләп табалар да:

«Бу эшне син эшләдеңме?» – дип сорыйлар.

Ибраһим галәйһиссәләм болай дип җавап бирә:

«Зур пот үзеннән башкага табынуларын теләми, шунлыктан бүтәннәргә бик ачулы иде. Ахыр чиктә ул, барысын да балта белән тураклап, балтаны иңбашына асып куя ала бит. Теләсәгез, әнә үзеннән сорагыз! Ни булганын үзе сөйләп бирсен!»[68]

Потпәрәст халык:

«Потлар сөйләшми ул!» – ди.

Шуннан соң Ибраһим галәйһиссәләм аларга:

«Ул очракта хәтта үзләрен дә саклый алмаган шушы гаҗиз нәрсәләр сезне ничек сакласын инде? Һаман да акылга килмисезме?» – ди.

Бу вакыйга Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә сурәтләнә:

فَرَاغَ إِلَى آلِهَتِهِمْ فَقَالَ أَلَا تَأْكُلُونَ. مَا لَكُمْ لَا تَنْطِقُونَ. فَرَاغَ عَلَيْهِمْ ضَرْبًا بِالْيَمِينِ

**«Ул (Ибраһим) илаһлары янына яшеренеп керде һәм әйтте: “Ашамыйсызмы? (җавап ишетмәгәч) Ни булды сезгә? Сез сөйләшмисезме?” Яннарына (яшерен генә) килеп, уң кулы белән ул аларга сукты»** («әс-Саффат», 91–93).

68. Карагыз: Табәри, «Тарих», I, 239; Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 97.

فَجَعَلَهُمْ جُذَاذًا إِلَّا كَبِيرًا لَهُمْ لَعَلَّهُمْ إِلَيْهِ يَرْجِعُونَ. قَالُوا مَنْ فَعَلَ هَذَا بِآلِهَتِنَا إِنَّهُ لَمِنَ
الظَّالِمِينَ. قَالُوا سَمِعْنَا فَتًى يَذْكُرُهُمْ يُقَالُ لَهُ إِبْرٰهِيمُ. قَالُوا فَأْتُوا بِهِ عَلَى أَعْيُنِ النَّاسِ
لَعَلَّهُمْ يَشْهَدُونَ. قَالُوا أَأَنْتَ فَعَلْتَ هَذَا بِآلِهَتِنَا يَا إِبْرٰهِيمُ. قَالَ بَلْ فَعَلَهُ كَبِيرُهُمْ هَذَا
فَاسْأَلُوهُمْ إِنْ كَانُوا يَنْطِقُونَ. فَرَجَعُوا إِلَى أَنْفُسِهِمْ فَقَالُوا إِنَّكُمْ أَنْتُمُ الظَّالِمُونَ. ثُمَّ
نُكِسُوا عَلَى رُؤُوسِهِمْ لَقَدْ عَلِمْتَ مَا هَؤُلَاءِ يَنْطِقُونَ. قَالَ أَفَتَعْبُدُونَ مِنْ دُونِ اللَّهِ مَا
لَا يَنْفَعُكُمْ شَيْئًا وَلَا يَضُرُّكُمْ. أُفٍّ لَكُمْ وَلِمَا تَعْبُدُونَ مِنْ دُونِ اللَّهِ أَفَلَا تَعْقِلُونَ.

**«Ул (Ибраһим) аларның иң зурысыннан башкаларын ватып чәлпәрәмә китерде, бәлки, алар аңа мөрәҗәгать итәрләр. Алар (потларның җимерелгәнен күргән халык): “Кем безнең илаһларыбызга моны эшләгән булса, ул – залимнәрдән”, – диделәр. Алар (халыкның бер өлеше): “Без Ибраһим исемле егетнең аларны һәрвакыт телгә алганын ишеткән идек”, – диделәр. Әйттеләр: “Аны кешеләрнең күзләре каршына китерегез. Бәлки, алар шаһитлык итәрләр”. (Соңыннан Ибраһимне алып килеп) алар: “И, Ибраһим! Безнең илаһларыбызга моны син эшләдеңме” – диделәр. (Ул) әйтте: “Юк! Моны менә бу иң зурлары эшләгәндер, сорагыз үзләреннән. Әгәр алар сөйләшә торган булсалар”. Алар үз-үзләренә мөрәҗәгать итеп: “Һичшиксез, сез үзегез бит залимнәр”, – диделәр[69]. Соңыннан (янә иске ышануларына һәм бәхәсләренә кире кайтып) башларын иеп: “Син үзең дә беләсең бит, алар сөйләшә алмыйлар”. (Ибраһим) әйтте: “Сез, Аллаһны калдырып, сезгә бернинди файда да, зарар да китерә алмаган нәрсәләргә табынасызмы әллә? Сезгә дә, Аллаһны калдырып табынган нәрсәләрегезгә дә, тфү! Һаман да аңламыйсызмыни (акылга килмисезме)?”»** («әл-Әнбия», 58–67).

Потларга табынучы халык Хәзрәти Ибраһимнең бу сүзләреннән потларны аның җимерүенә тәмам диярлек ышана. Бәдбәхет мәҗүсиләр бу эшкә түзеп тора алмыйча, таш кисәкләренең гаҗизлеген күреп, Хак Тәгаләгә юнәләсе урынга, Хәзрәти Ибраһимне кызып-кызып ачулана башлыйлар:

قَالُوا حَرِّقُوهُ وَانْصُرُوا آلِهَتَكُمْ إِنْ كُنْتُمْ فَاعِلِينَ

**«(Халыкның бер өлеше:) “Аны яндырыгыз һәм илаһларыбызга ярдәм итегез! Әгәр кылачак кешеләр булсагыз!” – диләр»** («әл-Әнбия», 68).

**Хәзрәти Ибраһимнең утка ыргытылуы**

Потпәрәст бәндәләр бу хәл турында Нәмрудка хәбәр итә. Шуннан соң Нәмруд Ибраһим галәйһиссәләмне чакыртып ала.

69. Бу аять болай дип тә аңлатыла: «Соңыннан бер-берсенә борылып: “(Потларны ялгыз һәм саксыз калдырган өчен), чын залим сез ул!” – дип, бер-берсен гаепләделәр».

Нәмруд янына кергән һәркем башта аңа сәҗдә кыла торган була. Ибраһим галәйһиссәләм исә сәҗдәгә китми. Кызыксыну катыш ачу белән моның сәбәбен сорагач, Нәмруд: «Сине һәм мине яралтучыдан кала башка берәүгә сәҗдә кылмыйм!» – дигән җавап ишетә.

Нәмруд: «Синең Раббың кем?» – дигәч, Ибраһим галәйһиссәләм: «Минем Раббым – терелтүче һәм үтерүче Аллаһ ул», – ди.

Нәмруд: «Мин дә терелтәм, мин дә үтерәм», – дип, зинданнан ике кеше китерттерә. Аларның берсен үтерә, икенчесен исә ireккә чыгара. Соңыннан: «Кара, мин дә шул ук эшне эшлим», – ди.

Ләкин юләр Нәмруд терелтүнең җан кертү, үтерүнең исә җанны алу икәнен белми. Ибраһим галәйһиссәләм: «Минем Раббым кояшны көнчыгыштан чыгара. Көчең җитсә, син көнбатыштан чыгар!» – ди.

Бу вакыйга Коръәни-Кәримдә болай бәян ителә:

أَلَمْ تَرَ إِلَى الَّذِي حَآجَّ إِبْرَهِيمَ فِي رَبِّهِ أَنْ آتَاهُ اللَّهُ الْمُلْكَ إِذْ قَالَ إِبْرَهِيمُ رَبِّيَ الَّذِي يُحْيِي وَيُمِيتُ قَالَ أَنَا أُحْيِي وَأُمِيتُ قَالَ إِبْرَهِيمُ فَإِنَّ اللَّهَ يَأْتِي بِالشَّمْسِ مِنَ الْمَشْرِقِ فَأْتِ بِهَا مِنَ الْمَغْرِبِ فَبُهِتَ الَّذِي كَفَرَ وَاللَّهُ لَا يَهْدِي الْقَوْمَ الظَّالِمِينَ

**«Аллаһ аңа падишаһлык (хакимият һәм байлык) бирде, дип, Раббысы хакында Ибраһим белән сүз көрәштергәнне (Нәмрудны) күрмәдеңме? Менә Ибраһим: “Минем Раббым – терелтүче дә, җаннарны алучы да!” – дигән иде. Ул исә: “Мин дә терелтәм дә, җаннарын да алам!” – диде. Ибраһим: “Һичшиксез, Аллаһ кояшны көнчыгыштан чыгара, син аны көнбатыштан чыгар!” – диде. (Шуннан соң) кяфер аптырашта калган иде. Аллаһ залимнәр кавемен һидәят итми»** («әл-Бәкара», 258).

Бу аяти кәримәдә Нәмрудның рәхмәтсезлеге, азгынлыгы һәм, Җәнабел-Хакка каршы сугыш игълан итеп, бунт күтәрүе белдерелә. Имам Бәйдави Нәмрудны җирдә үзен алла, дип уйлаган беренче ахмак дип саный. Бу идарәче Аллаһны инкяр итә, үзенә бирелгән мал-мөлкәткә шөкер кыласы урынга, рәхмәтсезлеген күрсәтә.

Ибраһим галәйһиссәләмнең Нәмруд белән очрашуы турында ике риваять бар:

1. Потларны җимергәч, Ибраһим галәйһиссәләмне кулга алалар. Утка ташлау өчен, аны Нәмруд янына алып киләләр.

2. Бер елны кытлык килә. Нәмруд халкына ризык тарата. Азык-төлек бирелгән һәр кешедән ул: «Раббың кем?» – дип сорый. Чират Ибраһим галәйһиссәләмгә җиткәч, пәйгамбәр: «Минем Раббым – терелтүче, гомер бирүче һәм үтерүче!» – ди.

Нәмрудның бу җавапка ачуы чыга һәм ул Хәзрәти Ибраһимгә ризык бирдерми. Пәйгамбәргә нинди җәза бирергә икәнен хәл итү өчен, ярдәмчеләрен җыеп, киңәшмә уздыра. Хәнун[70] исемле бер бәдбәхете:

«Аны зур учакта яндырыйк!» – дип тәкъдим итә.

Бу тәкъдим кабул ителә. Ут ягу өчен хәзерлек башлана. Бер ай буе утын ташыйлар. Надан һәм ахмак халык: «Бу бәндә безнең потларыбызга каршы чыга!» – дип, утын ташу эшендә бик бердәмлек күрсәтә. Утын тау булып өелә. Утның ялкыны күкләргә кадәр күтәрелә. Көйдергеч эсселеге аркасында хәтта кошлар да ул тирәдән очып уза алмый.

Бөтен әзерлекләр беткәч, халык утның бер башына җыела. Ибраһим галәйһиссәләм куллары богаулы, аяклары зынҗырлы хәлдә китерелә. Ләкин әлеге олуг пәйгамбәр «Хәлил» – Аллаһның дусты булганга күрә, бик авыр хәлдә калуына карамастан, Хак Тәгаләгә тәвәккәлли, бар булмышын Аңа багышлый. Күңелендә хәтта бераз гына да курку һәм борчылу сизелми.

Нәмруд һәм аның җәмәгате Ибраһим галәйһиссәләмнең утка ничек ыргытылачагы турында бәхәсләшеп ала. Ниһаять, зур катапульта ярдәмендә атарга карар кылалар.

Җирдәге һәм күктәге фәрештәләр аптырашта калып: «Йә, Раббы! Сине иң күп зикер кылучы Ибраһим галәйһиссәләмне утка ташлыйлар! Ул Сине бер мизгелгә дә онытмаган пәйгамбәр! Аңа ярдәм итәргә рөхсәт бирәсеңме, Аллаһым?» – дип ялваралар.

Аллаһ Тәгалә рөхсәт биргәч, бер фәрештә Ибраһим галәйһиссәләм янына килеп: «Җилләр миңа буйсындырылды. Теләгеңне әйтсәң, утны пыран-заран китерим!» – ди.

Башка бер фәрештә: «Сулар миңа буйсындырылды. Теләсәң, утны күз ачып йомган арада сүндерим!» – дип дәшә.

Тагын бер фәрештә: «Туфрак минем карамакка бирелде. Теләсәң, утны җиргә күмим!» – дип килеп җитә.

Ибраһим галәйһиссәләм исә бу фәрештәләргә:

«Дус белән дус арасына кермәгез! Раббым ни теләсә, мин шуңа риза! Коткара икән, Аның рәхмәтеннән. Яндыра икән, хата-кимчелегем аркасындадыр. Сабыр итүче булырмын, иншә Аллаһ!» – дип җавап бирә.[71]

Катапультага куелып, утка атылыр вакыт җиткәндә дә, Ибраһим галәйһиссәләм:

70. Мәлгунь Хәнун соңыннан җир астына күмелеп, һәлак була.
71. Карагыз: Әхмәд ибне Ханбәл, «Зүһд», 80; Табәри, «Тарих», I, 242; Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 99.

حَسْبُنَا اللّٰهُ وَنِعْمَ الْوَكِيلُ

«Безгә Аллаһ җитә, Ул нинди күркәм саклаучы», – ди.

Габдуллаһ ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмәнең риваятенә күрә, Ибраһим галәйһиссәләм бу сүзләрне утка ыргытылган чакта әйткән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу сүзләрне: *«Мөшрикләр сезгә каршы тупланды, саклану чарасын күрегез!»* – дигән вакытта телгә ала. Шуннан соң мөселманнарның иманнары ныгый һәм алар беравыздан: «Безгә Аллаһ җитә, Ул нинди күркәм саклаучы!» – дип, Аллаһка тиңсез буйсынучанлык үрнәге күрсәтәләр (Бохари, «Тәфсир», 3/13).

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләмне утка ташларга җыенган мизгелдә, Җәбраил галәйһиссәләм килеп, аннан: «Берәр теләгең бармы?» – дип сорый.

Ибраһим галәйһиссәләм:

«Әйе, бер үтенечем бар, ләкин сиңа түгел!» – дип җавап кайтара. Җәбраил галәйһиссәләм, Ибраһим галәйһиссәләмнең үз-үзен тотышына хәйран калып: «Ник Аллаһтан коткаруын сорамыйсың?» – ди.

«Ул минем хәлемне белә! Ут кемнең әмере белән яна? Яндыру кем эше?» – дип җавап бирә пәйгамбәр. Бер шагыйрь бу җавапны: «Билгеле булгач хәле, сораугa бармы хаҗәте!» – рәвешендә шигырь юлларына сала.

Аллаһ Тәгалә Ибраһим галәйһиссәләмнең фәрештәләрдән дә нәзакәтлерәк, сабыррак эш йөртеп, барлык үтенечләрен Аңа юнәлтүенә риза була, пәйгамбәрен Коръәни-Кәримдә:

وَإِبْرَهِيمَ الَّذِي وَفَّى

**«Сүзләрен төгәл үтәгән (антына тугры калган) Ибраһимнең дә»**, – дигән аяти кәримәсе белән мактап искә ала («ән-Нәҗем», 37).

Җәнабел-Хак шулай ук аны:

اِذْ قَالَ لَهُ رَبُّهُ أَسْلِمْ قَالَ اَسْلَمْتُ لِرَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Раббысы аңа: “Буйсын!” – дигән иде, ул исә: “Мин (бөтен булмышым белән) галәмнәрнең Раббысына буйсындым!” – дигән иде»**, аяти кәримәсе белән дә буйсынучанлык үрнәге буларак мактап уза («әл-Бәкара», 131).

**Утның гөлбакчага әйләндерелүе**

Ибраһим Хәлилуллаһның бу олуг буйсынучанлыгы һәм бары Хак Тәгаләгә генә тәвәккәл кылуы бәрабәренә, ул ут эченә төшеп җиткәнче, Аллаһ Тәгалә утка:

يَا نَارُ كُونِي بَرْدًا وَسَلَامًا عَلَى إِبْرَهِيمَ

**«...И, ут! Ибраһим өчен салкынлык һәм тынычлык бул!»** – дип әмер бирә («әл-Әнбия», 69).

Бу әмер килүгә, Ибраһим галәйһиссәләм килеп төшкән урын мизгел эчендә гөлбакчага әйләнә. Анда татлы чишмә гөрләп ага башлый. Бер риваятькә күрә, җәннәттән бер күлмәк иңдерелеп, ул Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләмгә кидерелә. Бу күлмәк соңыннан Исхак галәйһиссәләмгә, аңардан Ягъкуб галәйһиссәләмгә, аннары Йосыф галәйһиссәләмгә күчә. Ягъкуб галәйһиссәләмнең күзләре сукырайгач, Йосыф галәйһиссәләм җибәреп, атасының күзләрен ачтырган күлмәк әнә шул күлмәк була да инде.

Риваятькә күрә, утка: «Әй, ут! Ибраһим өчен салкынлык һәм тынычлык бул!» – дигән әмер килгәч, җирдәге бөтен утлар да билгеле бер вакытка суынып ала.[72]

Бу хәлдән соң Нәмруд гаҗәпкә кала һәм, дулкынланып: «Әй, Ибраһим! Синең илаһыңның бик бөек, Аның кодрәте һәм гыйззәте исә сине һәртөрле зарардан саклар дәрәҗәдә икәнен күрдем. Әй, Ибраһим! Синең Раббың нинди күркәм Раббы! Синең илаһыңа багышлап, хәзер дүрт мең сыерны корбан итеп чалдырачакмын!» – дип әйтә.

Ибраһим галәйһиссәләм исә: «Адашканлыктан туры юлга кайтып, тәүхид дингә килмичә, синең корбаннарыңның һичбер кыйммәте юк!» – ди. Ләкин Нәмруд: «Мөлкәтемне һәм хакимиятемне фида кыла алмыйм! Тик шулай да корбан чалдырачакмын!» – дип җавап кайтара.

Чыннан да, ул дүрт мең сыер чала һәм Ибраһим галәйһиссәләм белән көрәштән баш тарта.[73] Әмма хакимлек яратуы, тәкәбберлеге, артык горурлыгы һәм кирелеге аркасында иманга килми, бәдбәхет булып кала. Бер төркем потпәрәстләр, утның гөлбакчага әйләнү могҗизасын күргәч, иманга килә һәм илаһи җәзадан котыла.

Аллаһ Тәгалә ярдәме белән Нәмруд утыннан исән-сау котылган Ибраһим галәйһиссәләм иманга килмәгәннәргә Аллаһның газабы турында искә төшерә:

وَقَالَ إِنَّمَا اتَّخَذْتُم مِنْ دُونِ اللَّهِ أَوْثَانًا مَوَدَّةَ بَيْنِكُمْ فِي الْحَيوةِ الدُّنْيَا ثُمَّ يَوْمَ الْقِيَامَةِ
يَكْفُرُ بَعْضُكُم بِبَعْضٍ وَيَلْعَنُ بَعْضُكُم بَعْضًا وَمَأْوِيكُمُ النَّارُ وَمَا لَكُمْ مِنْ نَاصِرِينَ

**«Ул әйтте: “Сез дөнья тормышында бер-берегезне сөю аркасында Аллаһны калдырып потлар алдыгыз. Шуннан соң, Кыямәт көнендә берләрегез икенчеләрегезне танымаячак, кайберләрегез кайберләрегезне**

72. Карагыз: Табәри, «Тарих», I, 242; Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 99; Әхмәд ибне Ханбәл, «Зүһд», 80 б.
73. Диярбәкри, «Тариху Хамис», I, 83.

**ләгънәт итәчәк. Сыенасы урыныгыз – Ут (җәһәннәм)! Сезгә ярдәм итүчеләр булмаячак”»** («әл-Ганкәбут», 25).

**Ибраһим галәйһиссәләмнең һиҗрәте**

Утка ыргытылу вакыйгасыннан соң, Ибраһим галәйһиссәләм һәм аңа иман китерүчеләр иркен гыйбадәт кыла алсын, шулай ук Нәмруд һәм Кәлдани кабиләсенә җибәреләчәк илаһи газаптан саклансыннар өчен, Аллаһ Җәллә Җәләлүһү аларга күченеп китәргә боера. Ибраһим галәйһиссәләм һәм аңа ияргән мөэминнәр, кавемнәрен ташлап китеп, һиҗрәт кылырга карар бирә. Җәнабел-Хак аларның бу гамәлен мактап телгә ала:

قَدْ كَانَتْ لَكُمْ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ فِي إِبْرَاهِيمَ وَالَّذِينَ مَعَهُ إِذْ قَالُوا لِقَوْمِهِمْ إِنَّا بُرَءَؤُا مِنْكُمْ وَمِمَّا تَعْبُدُونَ مِنْ دُونِ اللَّهِ كَفَرْنَا بِكُمْ وَبَدَا بَيْنَنَا وَبَيْنَكُمُ الْعَدَاوَةُ وَالْبَغْضَاءُ أَبَدًا حَتَّى تُؤْمِنُوا بِاللَّهِ وَحْدَهُ

**«Сезгә Ибраһимдә һәм аның белән бергә булганнарда яхшы үрнәк булды. Менә алар кавемнәренә әйттеләр: “Без сездән дә, Аллаһны калдырып табынган нәрсәләрегездән дә еракбыз. Без сезне (ялган динегезне) инкяр иттек. Сез Аллаһның бер генә булганына иман китергәнчегә кадәр, безнең белән сезнең арада мәңгелек дошманлык һәм нәфрәт урнашты…”»** («әл-Мүмтәхәнә», 4).

Аллаһ Тәгалә шул рәвешле Хәлилен һәм мөэминнәрне тыныч, имин урынга җибәрә. Аяти кәримәләрдә бу хакта болай диелә:

فَآمَنَ لَهُ لُوطٌ وَقَالَ إِنِّي مُهَاجِرٌ إِلَى رَبِّي إِنَّهُ هُوَ الْعَزِيزُ الْحَكِيمُ

**«Лут аңа иман итте. Ул (Ибраһим) исә әйтте: “Һичшиксез, мин Раббыма (Ул кушкан җиргә) һиҗрәт итәм. Һичшиксез, Ул – Бөек, Хикмәт иясе”»** («әл-Ганкәбут», 26).

وَنَجَّيْنَاهُ وَلُوطًا إِلَى الْأَرْضِ الَّتِي بَارَكْنَا فِيهَا لِلْعَالَمِينَ

**«Без аны һәм Лутны галәмнәр өчен бәрәкәтле кылган җиргә ирештереп коткардык»** («әл-Әнбия», 71).

Лут Пәйгамбәр Хәзрәти Ибраһимнең бертуганының улы була. Пәйгамбәр булганлыгын исәпкә алганда, аның хакында элек кяферлектә йөреп, соңыннан гына иманга килгән, дип уйлау мантыйкка туры килми. Димәк, Хәзрәти Лутның Хәзрәти Ибраһимгә иман китерүен белдергән аятьтә Ибраһим галәйһиссәләмнең хаклыгын беренче булып раслаган зат – Лут галәйһиссәләм икәнлегенә ишарә ясала.

Ибраһим галәйһиссәләм Вавилонга, аннан исә Лут, Сара һәм бер төркем мөэминнәр белән бергә Урфаның көньягындагы Харран[74] бистәсенә һиҗрәт кыла. Лут галәйһиссәләм – аның туганының улы, Сара исә агасының кызы була.

Раббының кушканына ярашлы рәвештә, Ибраһим галәйһиссәләм Сара белән өйләнешә. Хәзрәти Сара күркәм әхлакка ия изге холыклы хатын була. Ибраһим галәйһиссәләмгә карата бик итагатьле мөнәсәбәт күрсәтә.

Ибраһим галәйһиссәләм соңрак, янә Аллаһның әмеренә буйсынып, хатыны Сара белән Димәшкъкә, аннан Мисырга күченә. Лут галәйһиссәләм исә, пәйгамбәр буларак, Содомга юл тота (Содом хәзерге Үле диңгез урынында була. Асты өстенә китерелгәнгә күрә, аяти кәримәдә «Мүэтәфикә» (кирегә әйләндерелгән) сүзе белән искә алына).

Мисыр белән Фиргавен гаиләсе идарә итә. Алар залим һәм тәкәббер затлар була. Читтән берәр матур хатын шәһәргә килсә, бу хакта шундук Фиргавенгә хәбәр ителә. Кияүдәге хатын булса, ире үтерелә, ир-ат туганы булса, хатынны аннан сорап алалар. Ибраһим галәйһиссәләм Сара анабыз белән чикне узуга, чибәр хатынның Мисырга килүе турында сарайга хәбәр җибәрелә. Сара анабыз турында Ибраһим галәйһиссәләмнән сорыйлар. Ә ул «дин кардәшем» дигән мәгънәдә аны «туганым» дип белдерә. Шуннан соң Ибраһим галәйһиссәләмгә кагылмыйлар, ә Сараны сарайга алып китәләр. Бохари җыентыгында бу вакыйга белән бәйле хәдис-шәрифтә болай дип бәян ителә:

*«Сара сарайга кергәч, шундук тәһарәт алып, ике рәкәгать намаз уку өчен, Аллаһ каршына баса. Намазны тәмамлагач, Җәнабел-Хакка болай дип ялвара: «И, Аллаһым! Мин Сиңа һәм Синең пәйгамбәреңә ышанган, гыйффәтемне дә иремнән кала башка һәркемнән бик тырышып саклаган бер колың икән, бу кяферне минем башыма бәла итмә!»* (Бохари, «Буйуэ», 100).

Фиргавен Сара янына килергә маташкач, шундук сулышы кысыла, паралич суга. Шул рәвешле Аллаһ Сараны аның явызлыгыннан саклый.

Фиргавен, куркуга калып, аны иреккә җибәрә. Хәтта җариясе Һаҗәрне аңа бүләк итеп бирә. Моңа аптыраган яраннарына: «Бу хатын – җен. Янымда тагын бераз торса, мине һәлак итәчәк иде. Аның зыян салуыннан саклану өчен, Һаҗәрне биреп җибәрдем!» – ди.[75]

Җәнабел-Хак без, колларына, изге гамәлләребез белән Аңа якынаерга һәм Аннан сабырлык белән ярдәм сорарга куша:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اسْتَعِينُوا بِالصَّبْرِ وَالصَّلٰوةِ

74. Харран иң башта Ибраһим галәйһиссәләмнең туганы Харран тарафыннан нигез салынганга күрә, шушы исемне йөртә.

75. Карагыз: Мөслим, «Фәдаил», 154.

**«И, иман китерүчеләр! Сабырлык һәм намаз аша (Аллаһтан) ярдәм сорагыз!..»** («әл-Бәкара», 153).

Әнә шул рәвешле Сара анабыз да, намаз һәм сабырлык белән Аллаһ Тәгаләгә ялваруы нәтиҗәсендә, бәладән котыла. Фиргавеннең кызы Хурья Хәзрәти Сараны бик ярата һәм аңа күпмедер асылташлар бүләк итә. Ибраһим галәйһиссәләм аларны күргәч:

«Боларны кире илтеп бир, болар безгә кирәкми», – ди. Бу сүзләрдән соң Сара аларны кире илтә. Хурья әлеге хәлне этисенә сөйләгәч, Фиргавен гаҗәпкә калып: «Һичшиксез, болар бик өстен һәм дәрәҗәле кавемнән. Пакь һәм абруйлы нәсел затлары», – ди.

Ибраһим галәйһиссәләм Сара һәм Һаҗәр белән бергә Мисырдан Палестинага кайта. Алар Сәбгъ дип йөртелгән тыныч, аулак җиргә урнаша. Ибраһим галәйһиссәләм кое казый. Аннан чиста, саф су чыга. Күпмедер вакыттан соң аларның ризыклары бетә. Ибраһим галәйһиссәләм шәһәргә юнәлә. Күпмедер барганнан соң, туктап уйлый да, акчасы булмагач, кире борыла. Сара белән Һаҗәр аны күргәч өметсезлеккә бирелмәсен өчен, капчыгына ком-таш тутыра. Үзләре урнашкан җиргә шул капчыкны күтәреп кайта. Бик арыган булганга, капчыкны куеп, шундук йокыга китә. Сара Һаҗәргә капчыкны ачарга куша. Капчыкта бодай булып чыга. Алар шундук күпмедер бодайны тартып, он ясыйлар һәм ипи пешерәләр. Ибраһим галәйһиссәләм уянгач, моңа бик аптырый һәм Раббысына шөкер итә.

Вакытлар узу белән, Сәбгъ бистәсендә бәрәкәт арта, Аллаһның нигъмәтләре күбәя. Бу тирәдән узып китүчеләр төпләнеп кала башлый һәм халык арта. Ләкин соңыннан, рәхмәтсез кыланып, Ибраһим галәйһиссәләмнең үзе казыган коесыннан аңа су бирми башлыйлар. Хәлилуллаһ моңа бик рәнҗи. Пәйгамбәрнең шулкадәр күңеле калуы аркасында, су кача. Бик зур корылык башлана. Мескен гафил бәндәләр, мондый хәл килеп тугач, үзләренең ваемсызлыкларына бик үкенеп, Ибраһим галәйһиссәләмнән гафу сорыйлар. Үзләре өчен ярлыкау сорап дога кылуын үтенәләр. Бик йомшак холыклы пәйгамбәр булган Ибраһим галәйһиссәләм, аларның үтенечен кабул итеп, Хак Тәгаләгә ялваргач, Аллаһның рәхмәте белән сулар кабат мул ага башлый.[76]

### Нәмрудның һәм Кәлдани кабиләсенең һәлак ителүе

Ибраһим галәйһиссәләм Вавилонга һиҗрәт кылгач, тәкәбберлекләре аркасында иманга килмәгән Кәлдани кавеме өстенә тузан өермәсе кебек черки көтүләре ябырыла. Алар потларга табынган халыкның канын суыра. Бәдбәхет потпәрәстләр тәмам корып-кибеп һәлак була. Бер чебен (черки) Нәмрудның борыны аша миенә керә. Үз-үзенә һәрчак ышанган Нәмруд, авыртуга чыдый

76. Карагыз: Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 90.

алмыйча, башына таяк белән суктыра һәм ахыр чиктә, шул таяк аркасында башы ярыла.

Коръәни-Кәримдә болай диелә:

وَأَرَادُوا بِهِ كَيْدًا فَجَعَلْنَاهُمُ الْأَخْسَرِينَ

**«Алар аңа (Ибраһимгә) зур бер хәйлә кылырга теләделәр, Без исә аларны иң зур зарар күргән кемсәләр хәленә төшердек»** («әл-Әнбия», 70).[77]

Дөньядагы хакимияте аркасында масайган, тәкәбберләнгән Нәмруд һәм аның кабахәт кавеме, бөтен кешелеккә гыйбрәт булып, тузандай вак чебен-черки тарафыннан каннары эчелеп, киптерелгән гәүдәләр хәленә китерелә.

**Кошларның терелүе**

Ибраһим галәйһиссәләм:

**«Йә, Раббы, үлеләрне терелтүдәге кодрәтеңне дөньялыктагы күзем белән күрергә телим!»** – дип ялвара.

Бу вакыйга Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә сурәтләнә:

وَإِذْ قَالَ إِبْرٰهِيمُ رَبِّ أَرِنِي كَيْفَ تُحْيِي الْمَوْتَى قَالَ أَوَلَمْ تُؤْمِنْ قَالَ بَلَى
وَلٰكِنْ لِيَطْمَئِنَّ قَلْبِي قَالَ فَخُذْ أَرْبَعَةً مِنَ الطَّيْرِ فَصُرْهُنَّ إِلَيْكَ ثُمَّ اجْعَلْ عَلَى كُلِّ
جَبَلٍ مِنْهُنَّ جُزْءًا ثُمَّ ادْعُهُنَّ يَأْتِينَكَ سَعْيًا وَاعْلَمْ أَنَّ اللّٰهَ عَزِيزٌ حَكِيمٌ

**«Заманында Ибраһим: “И, Раббым! Миңа үлеләрне ничек терелткәнеңне күрсәтче”, – дигән иде. Ул (Раббы) аңа: “Әллә син ышанмадыңмы?” – диде. Ул исә: “Әйе (инандым)! Вә ләкин күңелем тынычлансын (өчен күрергә теләдем)”, – дигән иде. Ул: “Дүрт кош ал һәм аларны үзеңә ияләндер. Шуннан (кискәләгәч) һәрбер тау башына алардан берәр кисәк куй. Шуннан аларны үзеңә чакыр, (күр) алар сиңа ашыгып киләчәкләр. Бел, һичшиксез, Аллаһ – Бөек, Хикмәт иясе”, – диде»** («әл-Бәкара», 260).

Ибраһим галәйһиссәләм инде үлгән берәр җан иясенең яңадан ничек тереләчәге белән кызыксына һәм Раббысыннан моны күрсәтүен сорый. Аллаһ Тәгалә аның догасына, аятьтә әйтелгәнчә, матди бер үрнәк белән җавап бирә, ләкин терелүнең асылын аңлатмый, чөнки кешенең аң-зиһене кабат терелүне тиешенчә төшенерлек дәрәҗәдә түгел. Моннан әүвәлге аятьләрдә искә алынганча, пәйгамбәрләргә бирелгән мондый үрнәкләр һәркайсы бер могҗиза булып тора. Иң мөһиме – Аллаһның бөтен җан ияләрен, аерым алганда, кешене һичшиксез терелтеп, хисап бирдерәчәгенә катгый иман китерү.

77. Шулай ук «әс-Саффат» сүрәсенең 98 нче аятен дә карагыз.

Шунысы да бар: һәрнәрсәгә көче җиткән Аллаһ Тәгалә, шәхсән үзе теләгән рәвештә терелткән һәм гомер биргән кебек, моны бәндәләр кулы белән дә эшли ала. Ибраһим галәйһиссәләмнең кулы белән чынга ашырылган үтерү-терелтү вакыйгасы әнә шуңа бер мисал буларак каралырга мөмкин. Шик юк:

رَبِّيَ الَّذِي يُحْيِي وَيُمِيتُ

**«…Минем Раббым – терелтүче дә, җаннарны алучы да…»** – дигән («әл-Бәкара», 258) Хәзрәти Ибраһим «И, Раббым!» дип әйткән вакытта: «И, гомер бирүгә һәм үтерүгә көче җиткән Раббым!» – ди, «Үлеләрне ничек терелтерсең?» дигәндә исә, бер яктан караганда: «Синең үлеләрне терелтүеңне беләм, фәкать моны ничек эшләгәнеңне белмәгәнлегемнән, Синең терелтүче сыйфатың минем аша да чынга аша аламыни икәнен беләсем килә? Миңа моны күрсәтүеңне сорыйм», – дип әйтә. Җәнабел-Хакның: «Әй, Ибраһим, әллә син ышнамадыңмы?» – дигән шелтәле кисәтүеннән соң, Хәзрәти Ибраһим: «Юк, йә, Раббы! Киресенчә, иман китердем. Син үзең теләгән вакытта миңа гомер биргән кебек, терелтүне дә күрсәтерсең. Ләкин күңелем тынычлансын өчен, ул иман сөенече белән йөрәгемә кергән өмет дәртен, дулкынлануны басу, иманнан анык белемгә, аннан исә күз белән күрү мөмкинлегенә ирешү өчен сорыйм», – ди һәм асыл максатының һәртөрле кер-пычрактан һәм кимчелекләрдән пакьләнгән йөрәккә ия булу һәм шул рәвешле «хулләт макамы»на (ихлас мәхәббәт һәм дуслык дәрәҗәсенә) ирешеп, мәңгегә Хәлилуллаһ (Аллаһ дусты) булып калудан гыйбарәт икәнлеген белдерә.

Акылның беренче вазифасы – Аллаһка иман китерү. Ләкин акыл нинди генә очракта да ул берәр чыганак, башлангыч нокта яки берәр нигез эзли. Акылны Хак Тәгаләнең кодрәтенә, бөеклегенә багышларга, Аның ныклы тоткасына ябышырга һәм хөкемнәренә буйсынырга кирәк.

Җәнабел-Хакның үлеләрне ничек терелтүен Ибраһим галәйһиссәләмнең күрергә теләве турында тагын берничә риваять бар. Сәгыйдь ибне Җүбәйр сүзләренчә, Аллаһ Тәгалә Ибраһим галәйһиссәләмгә «Хәлил» дәрәҗәсе биргәч, Җәбраил галәйһиссәләм аңа бу хакта шатлыклы хәбәр бирә. Ибраһим галәйһиссәләм:

«Моның нинди билгесе, үзенчәлеге бар?» – дип сорагач, Җәбраил галәйһиссәләм:

«Аллаһ Тәгалә синең догаңны кабул итәр. Догаң белән үлеләрне терелтер», – ди. Шуннан соң Ибраһим галәйһиссәләм:

«Йә, Раббы, үлеләрне ничек итеп терелтүеңне миңа күрсәтче!» – дип ялвара.

Хазин тәфсирендә мондый аңлатма бирелә:

Ибраһим галәйһиссәләм елга яр буенда бер хайван мәете күрә. Елгада вакытта аны су хайваннары ашый, дулкын белән ярга бәреп чыгаргач, коры җир хайваннары ашый икән. Хәлилуллаһ мондый хәлдә әнә шулай таралган кисәкләрнең ничек кире җыела алганын уйлый. Шуннан соң югарыда сурәтләнгән вакыйга була.

Әбуссогыд әфәнде тәфсирендә исә түбәндәгечә аңлатыла:

Нәмруд Ибраһим галәйһиссәләмнән: «Җан кертеп терелтүне һәм җаннарны алып үтерүне үз күзең белән күрдеңме?» – дип сорый. Ибраһим галәйһиссәләм дәшмичә тынып кала, шундук аңа әнә шул гыйбрәтле вакыйга күрсәтелә.

Җәнабел-Хак кушканча, Ибраһим галәйһиссәләм берәр баш тавис, карга, күгәрчен һәм әтәч ала. Аларның дүртесен дә суеп, кисәкләргә бүлә һәм һәркайсын берләштерә. Дүрт кисәк рәвешендә дүрт тау башына куя. Аннары һәркайсын үзенә чакыра. Кошлар барысы да аның янына очып килә.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм заманында да, үлеп кире терелүне инкяр итүче Убәй ибне Халәф, черегән бер сөякне кулында ваклаганнан соң, Рәсүлүллаһка таба борылып: «Аллаһның, шушы черегән сөякләрне кабат терелтәчәгенә ышанасыңмы?» – дип әйтә.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә:

*«Әйе, Аллаһ сине кабат терелтәчәк һәм җәһәннәмгә җибәрәчәк!»* – дип белдерә (Куртуби, «әл-Җамиг», XV, 58; Вахиди, 379 б.).

Аннары шушы аяти кәримәләр иңдерелә:

أَوَلَمْ يَرَ الْإِنْسَانُ أَنَّا خَلَقْنَاهُ مِنْ نُطْفَةٍ فَإِذَا هُوَ خَصِيمٌ مُبِينٌ. وَضَرَبَ لَنَا مَثَلًا وَنَسِيَ خَلْقَهُ
قَالَ مَنْ يُحْيِي الْعِظَامَ وَهِيَ رَمِيمٌ. قُلْ يُحْيِيهَا الَّذِي أَنْشَأَهَا أَوَّلَ مَرَّةٍ وَهُوَ بِكُلِّ خَلْقٍ عَلِيمٌ

**«Кеше Безнең аны бер тамчыдан яралтканыбызны күрмиме әллә? Ул ап-ачык дошманлык күрсәтә. Үзенең яралтылганын онытып, Безгә мисал китерә һәм: «Бу череп беткән сөякләрне кем терелтәчәк?» – дип әйтә. Әйт: «Аларны беренче мәртәбә Яралтучы терелтәчәк. Ул бит һәр яралтылган нәрсәне белүче»** («Йәсин», 77–79).

Мөфәссир Бәйдавинең сүзләренчә, шушы дүрт төрле кошны сайлап алуның мондый хикмәте бар:

Дөнья бизәкләренә һәм ләззәтләренә мәхәббәтне киметү һәм нәфеснең шәһвәтен тыю кирәклегенә ишарәләү өчен тавис кошы алынган. Явыз һөҗүмнәргә, кыерсыту һәм борчуларга китерә торган газап көчен тезгендә тоту кирәклегенә ишарәләү өчен, үпкәчеллек, кызып китү сыйфаты белән билгеле әтәчкә өстенлек бирелгән. Көнчелек һәм хөрмәтсезлек кебек тискәре

сыйфатларны җиңәргә кирәклегенә ишарәләү өчен, бу мәсьәләдә бер символга әйләнгән карга сайланган. Нәфеснең теләк-омтылышларын басарга кирәклегенә ишарәләү өчен күгәрчен тәкъдим ителгән. Димәк, бу кыйссада мәңгелек тормыш – ахирәттә бәхет-шатлыкка ирешергә омтылган затның нәфес теләкләрен тәрбияләргә, аларны яхшылыкка, игелеккә юнәлдерергә һәм Җәнабел-Хак ризалыгын алу өчен кулланырга тиешлеге белдерелә.

**Ибраһим галәйһиссәләмнең Һаҗәр анабыз белән гаилә коруы**

Ибраһим галәйһиссәләмнең Сара анабыздан баласы булмый. Инде яшьләре дә өлкәнәеп бара. Сара анабыз, җариясе Һаҗәрне азат итеп, аны Ибраһим галәйһиссәләмгә хатынлыкка бирә. Бу никахтан Хәзрәти Исмәгыйль дөньяга килә һәм Мөхәммәднең нуры Исмәгыйль галәйһиссәләмгә күчә. Сара анабыз исә бу нурның үзеннән күчәчәге турында хыялланып йөргән була, шуңа күрә бик кәефе кырыла. Ул Ибраһим галәйһиссәләмгә Һаҗәр анабызны башка бер бистәгә илтеп куярга куша. Ибраһим галәйһиссәләм, Аллаһның әмере белән, Һаҗәр анабызны һәм улы Хәзрәти Исмәгыйльне аулак бер шәһәрчек булган Мәккәгә алып килә. Җәбраил галәйһиссәләм пәйгамбәргә юл күрсәтеп бара. Мәккә урнашкан җиргә килеп җиткәч, Җәбраил:

«Әй, Ибраһим, гаиләңне монда урнаштыр!» – ди. Хәзрәти Ибраһим:

«Бу урын иген үстерергә дә, терлек асрарга да яраксыз бит», – дигәч, Җәбраил галәйһиссәләм:

«Әйе, шулай. Ләкин монда синең улың нәселеннән Өмми (укый-яза белмәгән) Пәйгамбәр чыгачак һәм “әл-кәлимәтүл-улья – иң бөек сүз булган тәүхид” аның белән тәмамланачак», – дип белдерә (Ибне Сәгъд, I, 164).

Имам Бохари хәзрәтләре Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмәдән бу вакыйгага бәйле риваять тапшыра:

*«Ибраһим галәйһиссәләм Һаҗәр анабызны һәм әле күкрәктән аерылмаган Исмәгыйль галәйһиссәләмне Мәккәгә алып килә. Гаиләсен киләчәктә шунда бәреп чыгачак Зәмзәм чишмәсе янындагы бер агач астында калдыра. Яннарына хөрмә тулы бер кәрҗин һәм су тулы кувшин куя. Аннары борылып кайтып китәргә юнәлә. Һаҗәр анабыз аңа артыннан сүзката: “Безне монда калдырырга Аллаһ куштымы?”*

*Ибраһим галәйһиссәләм: “Әйе!” – дип җавап бирә.*

*Һаҗәр анабыз Аллаһка ихлас буйсынучанлык һәм Аңа гына тәвәккәллек белән: “Ул очракта Раббым безне саклар! Безне юк итмәс!” – дип, Исмәгыйль галәйһиссәләм янына кайта.*

*Һаҗәр анабыз һәм Исмәгыйль галәйһиссәләм күздән югалгач, Ибраһим галәйһиссәләм, кулларын күтәреп, Раббысына түбәндәгечә ялвара:*

رَبَّنَا إِنِّي أَسْكَنْتُ مِنْ ذُرِّيَّتِي بِوَادٍ غَيْرِ ذِي زَرْعٍ عِنْدَ بَيْتِكَ الْمُحَرَّمِ رَبَّنَا لِيُقِيمُوا الصَّلٰوةَ فَاجْعَلْ أَفْئِدَةً مِنَ النَّاسِ تَهْوِي إِلَيْهِمْ وَارْزُقْهُمْ مِنَ الثَّمَرَاتِ لَعَلَّهُمْ يَشْكُرُونَ

***“И, Раббыбыз! Һичшиксез, мин нәселемнең бер өлешен игенсез бер үзәнлеккә, хәрам кылынган йортың (Кәгъбә) янында урнаштырдым. И, Раббыбыз! Намазларын (дөрес) укысыннар. Кешеләрдән кайберләренең күңелләрен авыштыр һәм аларны җимешләрдән ризыкландыр, – бәлки, алар шөкер итәрләр”»*** («Ибраһим», 37) (Бохари, «Әнбия», 9).

وَإِذْ قَالَ إِبْرَاهِيمُ رَبِّ اجْعَلْ هٰذَا بَلَدًا آمِنًا وَارْزُقْ أَهْلَهُ مِنَ الثَّمَرَاتِ مَنْ آمَنَ مِنْهُمْ بِاللّٰهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ قَالَ وَمَنْ كَفَرَ فَأُمَتِّعُهُ قَلِيلًا ثُمَّ أَضْطَرُّهُ إِلَى عَذَابِ النَّارِ وَبِئْسَ الْمَصِيرُ

**«”И, Раббым! Бу урынны иминлек шәһәре ит, анда яшәүчеләрнең Аллаһка һәм ахирәт көненә ышанганнарын җимешләрдән ризыкландыр!” – дигән иде. Ул (Ибраһимнең догасын кабул иткән Аллаһ): “Кем кяфер булса, аны (дөнья нигъмәтләреннән) бик аз файдаландырырмын, шуннан соң аны Утның (җәһәннәм) газабына мәҗбүр итәрмен. Бу барасы урын нинди яман!” – дигән иде!»** («әл-Бәкара», 126).

Аллаһ дөньялыкта Аны инкяр итүчеләрне дә ризыкландыра, дөнья нигъмәтләрен теләгән кадәр кулланырга мөмкинлек бирә. Бу очракта дөнья нигъмәтенә ия булу-булмау диндарлыкка бәйле түгел. Нигъмәтләр мөэмингә дә, кяфергә дә бирелә. Дөнья нигъмәтләре – сынау өчен бер нигез, сәбәп. Хәерле, яхшы булу-булмаулары аларның нәтиҗәсенә бәйле. Байлык һәм хакимият ихлас коллык, гыйбадәт өчен сәбәпкә әйләнсә, бу – ике дөнья бәхете дигән сүз. Әмма азгынлыкка, юлдан язуга китерсә, мәңгелек тормышны таркатыр, бәхет урынына кайгы-бәла китергән булыр.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Ибраһим галәйһиссәләмнең догасын кабул итә. Бу дога нәтиҗәсендә хәзер хаҗ һәм гомрә кылган мөэминнәрнең күңелләренә бу калага мәхәббәт тула һәм җаннар тынычлыкка, иминлеккә тиенә. Мәдинә Мөнәвварә төбәге исә бәрәкәткә ирешеп, хөрмә һәм башка төрледән-төрле җиләк-җимешләр белән тула.

Ибраһим галәйһиссәләмнең бу ялваруы шулай ук аннан Зәмзәм суының бәреп чыгуына да бер сәбәп була.

Ибраһим галәйһиссәләм алып килгән кувшинда су бетә. Һаҗәр анабыз Сафа белән Мәрвә калкулыклары арасында җиде тапкыр йөгереп уза. Бу ике калкулык арасы дүрт йөз метр чамасы тәшкил итә. Һаҗәр анабыз бер йөгерә, бер Хәзрәти Исмәгыйльгә карый. Ул тирәдә кеше түгел, хәтта очар кош та булмый. Һичкайда тормыш әсәре күренми. Һаҗәр анабыз Мәрвә түбәсенә күтәрелгәч: «Дәшмә һәм яхшылап тыңла!» – дигән бер тавыш ишетә. Бу

Җәбраил тавышы була. Һаҗәр анабыз шундук тавыш килгән якка борыла. Җәбраил галәйһиссәләм сүзен дәвам итә: «Сез һәрнәрсәгә кодрәтле булучыга әманәт! “Бетәбез”, дип курыкма! Бу – Бәйтуллаһ (Аллаһ йорты) урыны. Ул йортны шушы бала белән атасы төзиячәк. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү бу йортның иясен ташламас!» – ди.

Һаҗәр анабыз әлеге мөрәҗәгатьтән соң улы Исмәгыйль янына юнәлә. Исмәгыйль галәйһиссәләмнең аяк очыннан су бәреп чыкканын күрә. Һаҗәр анабыз бик сөенеп, Раббысына шөкер итә. Су агып бетәр, дип куркып, читләренә бераз ком өя. Суга «тукта, тукта» дигән мәгънә белдергән «Зәм, зәм», дия-дия, аны агып бетүдән сакларга тырыша.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди:

*«Аллаһ Исмәгыйльнең анасы Һаҗәргә рәхмәт кылсын! Әгәр ул Зәмзәмне шул хәлендә калдырып, суның тирә-ягын уратып алмаган булса, һичшиксез, Зәмзәм гел агып торган бер чишмә булыр иде»* (Бохари, «Әнбия», 9).

Аллаһка буйсынучанлык һәм үзеңне Аңа багышлау нәтиҗәсе буларак бәреп чыккан бу су кыяматкәчә өммәткә шифасын биреп торачак.

Шул рәвешле Ибраһим галәйһиссәләм һәм Һаҗәр анабыз үзләренең Аллаһка ихлас буйсынучанлыклары нәтиҗәсендә бик зур бәрәкәткә ирешә. Бу бәрәкәтнең тагын бер чагылышы исә, Һаҗәр анабызның Сафа белән Мәрвә арасында йөгереп йөрүе – сәгый гамәленең кыяматкәчә башкарылачак бөтен хаҗ һәм гомрә гыйбадәтләренең бер рөкене буларак саклануыннан гыйбарәт.

Ана белән угыл корылыгы белән билгеле аулак җирлектә яшәүләрен дәвам итә. Шуннан үтеп барган Җүрһүми кабиләсе бер кошның гел бер урынга төшкәнлеген һәм соңыннан кабат шуннан һавага күтәрелгәнен күреп ала. Моның бер тормыш әсәре ихтимал урын икәнен чамалап, ул тирәгә ике кеше җибәрәләр. Килүчеләр, Зәмзәм суын күргәч, Һаҗәр анабыздан: «Монда урнаша алабызмы?» – дип рөхсәт сорыйлар. Һаҗәр анабыз, «суны үз милкең дип белдермәү» шарты белән, рөхсәт бирә. Шул рәвешле җүрһүмиләр Мәккәгә килеп төпләнгән тәүге кабилә була.

### Корбан сынавы

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм Вавилоннан Димәшкъкә барганда:

وَقَالَ إِنِّي ذَاهِبٌ إِلَى رَبِّي سَيَهْدِينِ. رَبِّ هَبْ لِي مِنَ الصَّالِحِينَ

**«”Мин Раббыма китәмен.[78] Һичшиксез, Ул мине һидәят итәчәк. И, Раббым! Изгеләрдән берсен (бер бала) миңа бир!” – дип әйтә»** («әс-Саффат», 99–100).

78. Ибраһим галәйһиссәләм монда Раббысына туп-туры барырга теләгәнен белдерә. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хакында исә:

Монда иң бөек дус белән күрешү өчен, ихлас йөрәк, ягъни күңел дөньясы белән сәфәр кылынуына ишарә ясала. Моннан соң килгән аяти кәримәләрдә Хәзрәти Исмәгыйльнең шатлыклы хәбәр алу һәм корбан ителү вакыйгасы түбәндәгечә тасвирлана:

فَبَشَّرْنَاهُ بِغُلَامٍ حَلِيمٍ. فَلَمَّا بَلَغَ مَعَهُ السَّعْيَ قَالَ يَا بُنَيَّ إِنِّي أَرَى فِي الْمَنَامِ أَنِّي أَذْبَحُكَ فَانْظُرْ مَاذَا تَرَى قَالَ يَا أَبَتِ افْعَلْ مَا تُؤْمَرُ سَتَجِدُنِي إِنْ شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّابِرِينَ. فَلَمَّا أَسْلَمَا وَتَلَّهُ لِلْجَبِينِ. وَنَادَيْنَاهُ أَنْ يَا إِبْرَهِيمُ. قَدْ صَدَّقْتَ الرُّؤْيَا إِنَّا كَذَلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ. إِنَّ هَذَا لَهُوَ الْبَلَاءُ الْمُبِينُ. وَفَدَيْنَاهُ بِذِبْحٍ عَظِيمٍ. وَتَرَكْنَا عَلَيْهِ فِي الْآخِرِينَ. سَلَامٌ عَلَى إِبْرَهِيمَ. كَذَلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ. إِنَّهُ مِنْ عِبَادِنَا الْمُؤْمِنِينَ

**«Без аны йомшак холыклы бер ир бала белән сөендердек. Ул аның (атасы) белән бергә тырышлык куюга җиткәч (атасы): “И, улым! Һичшиксез, мин төшемдә сине чалганымны күрдем. Син ни уйлаганыңны кара”, – диде. Ул (җавабында): “И, әтием! Сиңа әмер ителгән нәрсәне үтә. Иншә Аллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табачаксың”, – диде. Алар икесе буйсынгач, ул (Ибраһим) аны яны белән яткырды. Без аңа дәштек: “И, Ибраһим! Син төшне акладың. Һичшиксез, игелек кылучыларга Без шулай әҗерләрен бирәбез. Һичшиксез, бу – ап-ачык (авыр) бер сынау. Без аңа фидия итеп зур бер корбанлык бирдек. Соңгылар (киләчәк нәселләр) арасында да аның турында (яхшы исем) калдырдык. Ибраһимгә сәлам булсын! Һичшиксез, игелек кылучыларга Без шулай әҗерләрен бирәбез. Чөнки, һичшиксез, ул – Безнең инанган колларыбыздан”»** («әс-Саффат», 101–111).

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм, Һаҗәр анабыз белән Исмәгыйль галәйһиссәләмне Мәккәдә калдырып киткәннән соң, хатыны Сара янына кайта. Вакыт-вакыт алар янына барыштыра. Бер сәфәрендә чакта Мәккәдә төш күрә. Бу төшендә, аятьтә әйтелгәнчә, Исмәгыйль галәйһиссәләмне корбан итеп китерә. Ибраһим галәйһиссәләм төшнең Аллаһтанмы, шайтаннанмы икәнлегенә шикләнә.[79] Ләкин бер үк төш өч көн дә кабатлана. Бу көннәр хаҗ вакытының тәүрия, гарәфә һәм корбан бәйрәменең беренче көненә туры килә.

Бер риваятьтә әйтелгәнчә, Ибраһим галәйһиссәләм: «Аллаһ миңа бер ир бала бирсә, аны корбан итәчәкмен!» – дип әйткән була. Әнә шул сүзе сәбәпле сынала да.[80]

---

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَى بِعَبْدِهِ لَيْلاً مِنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا

«Аятьләребездән кайберләрен (аңа) күрсәтик, дип, бер төнне колын (Мөхәммәдне) Хәрам мәчетеннән Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән Әкъса мәчетенә күчерүче (Аллаһ) кимчелекләрдән пакь...» – дип («әл-Исра», 1), ул мөбарәк затның шәхсән Раббы тарафыннан бөек урынга, дәрәҗәгә күтәрелгәнлеге турында хәбәр бирелә.

79. Карагыз: Рази, XXVI, 133; Алуси, «Рух әл-Мәгани», XXIII, 128.
80. Карагыз: Рази, XXVI, 133; Табәри, «Тарих», I, 272-273; Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 111.

Раббысыннан илаһи әмер килгәч, Ибраһим галәйһиссәләм Һаҗәр анабызга улы Исмәгыйльне юарга һәм хушбуйлар сөртергә куша, аны бер дусты янына алып барачагын әйтә. Хәзрәти Исмәгыйльгә исә: «Улым, Аллаһ ризалыгы өчен корбан чалачакмын!» – дип, үзе белән бер бау һәм пычак алырга кирәклеген әйтә.

Алар Гарәфәт тавында хаҗиләр вәкыфта басып тора торган җиргә таба юл тоталар. Шулвакыт шайтан кеше рәвешендә Һаҗәр анабыз янына килә һәм Аңа: «Ибраһим улыңны кая алып барганын беләсеңме?» – ди. Ул исә: «Дусты янына алып бара», – дип җавап бирә. Шайтан: «Юк, ул аны суярга алып китте», – ди. Һаҗәр анабыз: «Ул улын бик ярата!» – дип каршы килә. Шайтан, сүзен дәвам итеп: «Аллаһ кушкан өчен суячак ул!» – дигәч, Һаҗәр анабыз: «Әгәр Аллаһ Җәллә Җәләлүһү кушкан икән, күркәм эштер. Буйсынырбыз», – ди.

Һаҗәр анабызны алдау хәленнән килмәгәч, шайтан Исмәгыйль галәйһиссәләм янына китә. Бу юлы аннан сорый: «Әтиең сине кая алып барганын беләсеңме?» Исмәгыйль галәйһиссәләм: «Дустын зиярәт кылырга», – ди. Шайтан: «Юк, сине суярга алып бара. Раббысы аңа шундый әмер биргән, дип уйлый!» – ди. Шуннан соң Хәзрәти Исмәгыйль: «Аллаһ әмер иткән икән, моны бик сөенеп башкарырбыз!» – дип шайтанны таш ыргыта-ыргыта куып җибәрә.

Шайтан Исмәгыйль галәйһиссәләмне дә котырта алмый. Бу юлы инде Ибраһим галәйһиссәләмгә дәшә: «Әй, картлач! Улыңны кая алып барасың? Сине төшеңдә шайтан котырткан! Ул шайтани төшләр», – ди. Ибраһим галәйһиссәләм: «Син – шайтан! Хәзер үк күзебездән югал!» – ди. Ул кулына җидешәр таш алып, шайтанны өч төрле урында шуларны ыргыта-ыргыта куа. Хаҗның кыяматкәчә бер рөкене булып сакланачак шайтанны таш белән куу шул рәвешле башланып китә. Бу гамәл, аларның буйсынучанлыгының һәм Аллаһка тәвәккәллекләренең чагылышы буларак, бөтен өммәт өчен үрнәккә әйләнә.

Ибраһим галәйһиссәләм Исмәгыйль галәйһиссәләм белән бергә Минадан Гарәфәт тавына таба барганда, күктәге фәрештәләр шактый борчыла-дулкынлана. Алар, бер-берсенә аптырашып: «Сөбханаллаһ! Бер пәйгамбәр икенче бер пәйгамбәрне корбан итәргә алып бара!» – диешәләр.

Ибраһим галәйһиссәләм улы Хәзрәти Исмәгыйльгә:

«Әй, улым! Төшемдә сине корбан итәргә әмер алдым», – дип, бу эшнең асылын сөйләп бирә.

Исмәгыйль галәйһиссәләм:

«Әтием, моны сиңа Аллаһ куштымы?» – дип сорый. Ибраһим галәйһиссәләм:

«Әйе!» – ди. Шуннан соң Исмәгыйль галәйһиссәләм:

«Әтием! Син кушылганны эшлә! Иншә Аллаһ, мине сабыр итүчеләрдән табырсың!» – дип, җанын фида кылырга әзер икәнлеген белдерә. Әтисен тынычландырган бу сүзләрдән соң:

«Әй, әтием! Нәмруд сине утка ташлаганда – сабыр иттең. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү синнән риза булды. Мин дә корбан булырга ризамын. Иншә Аллаһ, мине сабыр итүче дип табарсың. Синнән аерылгач – Раббым белән; дөнья нигъмәтләреннән аерылгач, җәннәт белән кавышачакмын! Мин үз кулың белән корбан итәчәк улыңның авыртуын гомер буе онытa алмавыңа гына кайгырам. И, әтием, алданрак әйткән булсаң, әнием белән дә хушлашыр идек!» – ди.

Ибраһим галәйһиссәләм:

«Улым, әниең каршы килер, дип, моннан баш тарттым!» – ди.

Ул вакытларда Исмәгыйль галәйһиссәләмгә җиде яки унөч яшь чамасы була.[81]

Риваятьтә болай тапшырыла:

«Аллаһ Тәгалә, Ибраһим галәйһиссәләмгә җир һәм күкләрне күрсәткән вакытта, пәйгамбәр Аллаһка каршы килгән, киреләнгән берәүне күрә. Һәм аны һәлак итсен өчен, Аллаһка дога кыла. Аллаһ Тәгалә аны һәлак итә. Ибраһим галәйһиссәләм башка бер кяферне дә күрә. Аңа да бәддога укый һәм ул бәндә дә һәлак була. Аллаһка буйсынмаган тагын берәүне күрә, аның да һәлак ителүен сорый, ул бәндә дә һәлак ителә. Шул рәвешле берничә кеше һәлак була.[82] Шуннан соң Җәнабел-Хак Ибраһим галәйһиссәләмгә мондый вәхи иңдерә:

«Әй, Ибраһим! Һичшиксез, син – догасы кабул ителә торган зат! Колларым һәлак булсын өчен, Миңа дога кылма! Чөнки аларның Минем каршымда өч үзенчәлеге бар:

1. Бәндә, бәлки, кылганнарына тәүбә итәр, Мин исә тәүбәсен кабул итәрмен;

2. Яки аның дәвамчыларыннан Мине зикер итәчәк нәсел туар;

3. Яисә кыямәт көнне, теләсәм, аны гафу итәрмен, теләсәм, җәзалармын» («әт-Тәфсир мин Сүнәни Сәид ибне Мансур», V, 29).

Аллаһ Тәгаләнең Ибраһим галәйһиссәләмгә улын корбан итәргә кушуында бер сәбәп, югарыда телгә алган вакыйгадагы кебек, Хәзрәти Ибраһимнең Хак Тәгаләгә каршы баш күтәргән бәндәләргә карата мәрхәмәтсез булуыннан да, дип әйтәләр.

81. Карагыз: Хаким, «Мүстәдрәк», II, 605-606; Табәри, «Тарих», I, 263–278.
82. Карагыз: Гали әл-Муттакый, IV, 269/10449; Алуси, «Рух әл-Мәгани», VII, 197.

Бүтән бер риваятьтә болай бәян кылына:

وَكَذَلِكَ نُرِي إِبْرَهِيمَ مَلَكُوتَ السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ وَلِيَكُونَ مِنَ الْمُوقِنِينَ

**«Шиксез иман китерсен, дип, Без Ибраһимгә күкләрнең һәм җирнең мөлкәтләрен күрсәттек»**, дигән аятьтә әйтелгәнчә («әл-Әнгам», 75), Ибраһим галәйһиссәләм һәр төн күккә күтәрелә. Шундый бер төнне аны янә күккә алып менәләр. Ул яман эшләр эшләгән бер гөнаһлы бәндәне күрә дә әйтә:

«И, Аллаһыбыз! Бу адәм Синең ризыгыңны ашый, Синең җиреңөстеннән йөри, шуңа карамастан ,кушканнарыңны үтәми. Аны һәлак ит!»

Аллаһ Тәгалә ул бәндәне һәлак итә. Хәзрәти Ибраһим бүтән бер гөнаһлы затны да күреп, һәлак ителүен сорагач, аңа шундый мөрәҗәгать кылә:

«Әй, Ибраһим! Колларым һәлак булсын өчен бәддога укудан баш тарт! Аларга вакыт биреп, йомшаграк бул! Чөнки Мин аларның буйсынмаганлыкларын һәрдаим күреп торсам да, барыбер һәлак итмим!»

Җиргә төшерелгәч, Ибраһим галәйһиссәләм Коръәни-Кәримдә искә алынган төшен күрә. Улының, олуг буйсынучанлык күрсәтеп: «Үзеңә кушылганны үтә, әтием!» – дигән сүзләреннән соң, Хәлилуллаһ улын корбан итеп суярга әзерләнә һәм, кулына пычагын алып, болай ди:

«И, Аллаһым! Бу минем улым. Йөрәгем парәсе һәм минем өчен кешеләрнең иң сөеклесе».

Шул мизгелдә мондый тавыш ишетә:

«Син Минем колымның һәлак ителүен сораган төнне хәтерлисеңме? Син улыңа карата шәфкатьле булган кебек, Минем дә колларыма карата шәфкатьле һәм мәрхәмәтле булуымны белмисеңме? Син Миннән колымны һәлак итүемне сораган идең. Хәзер Мин дә синең улыңны корбан итүеңне телим!» (Рамазаноглу М. Сами, «Ибраһим галәйһиссәләм», 44–46 б.; шулай ук карагыз: Саләби, «Тәфсир», IV, 161).

Аллаһ кушканга корбан итеп чалынырга тиешле Исмәгыйль галәйһиссәләм Ибраһим галәйһиссәләмгә болай ди:

«И, әтием! Берничә үтенечем бар:

1. Кулларымны һәм аякларымны әйбәтләп бәйлә, җан ачысы белән тыпырчынып, берәр хата кылып куймыйм.

2. Итәк-җиңнәреңне җыеп куй, өстеңә каным чәчрәмәсен.

3. Җан бирү җиңел килсен өчен, пычагың үткен булсын! (Бу авыр эш) синең өчен дә тизрәк тоелыр.

4. Пычакны сызганда, йөземә карама! Бәлки, аталык шәфкате белән миңа мәрхәмәт тоеп, түзеп тора алмыйча, Аллаһның әмерен үтәүне соңартырсың.

5. Күлмәгемне әниемә алып кайт! Шуннан бер юаныч тапсын! Аңа: "Улың шәфәгать иясе буларак Аллаһ каршына китте", – диярсең!»[83]

Бу сүзләрне тыңлаганда, Ибраһим галәйһиссәләмнең күзләреннән яшь ага. Бик нык елагач, ул:

«Балакаем, син миңа Аллаһ кушкан эштә нинди зур ярдәм күрсәттең!» – ди. Аннары кулларын күтәреп:

«Йә, Раббы, миңа бу хәлем аркасында сабырлык бир! Картлыгым сәбәпле миңа рәхмәт әйлә!» – дип дога кыла.

Исмәгыйль галәйһиссәләм исә:

«Йә, Раббы, миңа бу эштә сабырлык һәм түземлек бир!» – дип дога кыла.

Аннары Исмәгыйль галәйһиссәләм әйтә:

«Әтием, күк капуслары ачылды. Фәрештәләр, хәйран калып, Аллаһка сәҗдә кылалар: "Йә, Раббы, Синең ризалыгың өчен бер пәйгамбәр икенче бер пәйгамбәрне корбан итеп чалырга җыена... Син аларга мәрхәмәтле бул!" – дип ялваралар».

Шуннан соң:

«Әтием, мәхәббәтнең шарты – кушкан эшне вакытында башкаруында! Әйдә, үзеңә кушылганны үтә!» – дип әтисенә көч бирә.

Ибраһим галәйһиссәләм Исмәгыйль галәйһиссәләмне җиргә яткыра:

«И, балакаем! Кыяматкәчә синең белән хушлашам! Кабат күрешү кыямәт көнне булыр!» – дип, Исмәгыйль галәйһиссәләмнең бугазына пычак белән бар көченә сызып җибәрә. Шул мизгелдә Аллаһ Тәгалә Җәбраилгә:

«Өлгер! Пычакны борып җибәр!» – дип боера. Җәбраил галәйһиссәләм мизгел эчендә күктән төшеп, пычакны читкә бора. Ибраһим галәйһиссәләм исә янә хәленнән килгәнчә пычакны тартып җибәрә, тик пычак бу юлы да кисми.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү:

«Ибраһим, чыннан да төшен раслады, тугрылык күрсәтте», – ди.

Шуннан соң илаһи әмер белән Җәбраил галәйһиссәләм мизгел эчендә җәннәттән бер сарык иңдерә һәм тәкбир әйтә:

83. Карагыз: Табәри, «Тарих», I, 275; Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 112; Хаким, «Мүстәдрәк», II, 606, № 4040.

اَللّٰهُ أَكْبَرُ اللّٰهُ أَكْبَرُ

Ибраһим галәйһиссәләм, бу тәкбирне ишеткәч, аны дәвам итә:

لَا اِلَهَ اِلَّا اللّٰهُ وَاللّٰهُ أَكْبَرُ

Исмәгыйль галәйһиссәләм дә кушыла:

اللّٰهُ أَكْبَرُ وَ لِلّٰهِ الْحَمْدُ

Шулай итеп, гарәфә көнне иртәнге намаздан башлап корбан бәйрәменең дүртенче көнендәге икенде намазына кадәр дәвам иткән «тәшрик тәкбире» әйтүгә нигез салына.

Ата белән угыл, шөкер итә-итә, өйләренә кайта. Һаҗәр анабыз белән Исмәгыйль галәйһиссәләм кочаклашып күрешә. Ибраһим галәйһиссәләм исә кабат Сара анабыз янына кайтып китә.

Утка атылып, Ибраһим галәйһиссәләмнең нәфесе сынала, корбан чалу әмере килгәч, баласы белән имтихан уза. Аллаһка буйсынучанлыгы һәм үзен Аңа гына багышлавы ике сынауны уңышлы тапшырырга булыша. Чират байлык белән сыналуга җитә. Бер риваятькә күрә, Ибраһим галәйһиссәләмнең 12000 хайваннан гыйбарәт көтүе була. Бу көтүләрне бик күп каравылчы этләре саклый. Үзләрен дөньялыкка багышлаганнарны кисәтү, кимсетү максатында, ул этләренә алтын муенчак тага. Җәбраил галәйһиссәләм кеше кыяфәтендә килә дә:

«Бу кемнең көтүләре?» – дип сорый.

Ибраһим галәйһиссәләм:

«Раббымныкы. Мин исә аманәткә алучымын!» – ди. Җәбраил галәйһиссәләм:

«Миңа сатасыңмы?» – ди. Ибраһим галәйһиссәләм:

«Раббымны бер тапкыр зикер ит, өчтән берен бирермен, өч мәртәбә зикер итсәң; бөтенесен дә бирәм!» – ди.

Җәбраил галәйһиссәләм әйтә:

سُبُّوحٌ قُدُّوسٌ رَبُّنَا وَرَبُّ الْمَلٰئِكَةِ وَالرُّوحِ

Ибраһим галәйһиссәләм:

«Ал, бөтенесе дә синеке, алып кит!» – ди. Җәбраил галәйһиссәләм:

«Мин фәрештә, ала алмыйм!» – ди.

Шуннан Ибраһим галәйһиссәләм әйтә:

«Син – фәрештә, ә мин – Хәлил. Биргәнемне кире ала алмам!» – ди.

Ниһаять Ибраһим галәйһиссәләм көтүләрне сата. Бик киң мәйданда җир ала. Аны мөселманнар файдасына куллануга бирә. Шул рәвешле Ибраһим галәйһиссәләмнән вакыф[84] гамәле башлана.

Аллаһның Хәлиле булган Ибраһим галәйһиссәләм, Аллаһ ризалыгы өчен бөтен байлыгын мизгел эчендә корбан итеп, мал белән сынауны да уза, үзенең чын дус – Хәлил икәнен кабат исбатлый. Ибраһим галәйһиссәләмнең бу сыйфаты аяти кәримәдә болай дип искә алына:

وَإِذِ ابْتَلَى إِبْرَاهِيمَ رَبُّهُ بِكَلِمَاتٍ فَأَتَمَّهُنَّ

**«Бервакыт Раббысы Ибраһимне кайбер сүз (әмерләр һәм тыюлар) белән сынаган һәм ул (Ибраһим) аларны үтәгән иде…»** («әл-Бәкара», 124).

**Исхак галәйһиссәләмнең тууы**

Ибраһим галәйһиссәләм, Раббысына биргән сүзенә тугрылыгын күрсәтеп, улын корбан итәргә риза булганы өчен, шактый картайган булуына карамастан, Аллаһ Тәгалә аңа тагын бер ир бала бүләк итә. Аяти кәримәләрдә әлеге илаһи бүләк турында болай диелә:

وَبَشَّرْنَاهُ بِإِسْحٰقَ نَبِيًّا مِنَ الصَّالِحِينَ. وَبَارَكْنَا عَلَيْهِ
وَعَلَى إِسْحٰقَ وَمِنْ ذُرِّيَّتِهِمَا مُحْسِنٌ وَظَالِمٌ لِنَفْسِهِ مُبِينٌ

**«Изгеләрдән бер пәйгамбәр булачак Исхак белән Без аны (Ибраһимне) сөендердек. Аңа да, Исхакка да бәрәкәт яудырдык. Әмма икесенең нәселеннән дә игелек кылган да, үз-үзенә ап-ачык золым иткән дә бар»** («әс-Саффат», 112–113).

Ул вакытта Ибраһим галәйһиссәләмгә – 120, Сара анабызга 90 яки 99 яшь була.

Ибне Габбасның риваятенә күрә, Җәбраил белән бергә бер төркем фәрештә, Исхак галәйһиссәләм турында шатлыклы хәбәр ирештереп, Ибраһим галәйһиссәләмне сөендерә. Аннары исә Лут кавемен һәлак итәргә юнәләләр.

Фәрештәләр, Ибраһим галәйһиссәләмне зиярәт кылу өчен, кеше кыяфәтендә кунак булып килә. Ибраһим галәйһиссәләм, тана ите кыздырып, алар-

84. Вакыф (вакф) – Яралтучыдан бигрәк яралтканнарга карата мәрхәмәт, шәфкать һәм мәхәббәтнең бер оешма рәвешен алуы ул. Башка сүз белән әйткәндә, Аллаһка атап бирелгән, анык бер милек иясенеке дип тану тыелган мал-мөлкәт ул. Бу мөлкәтне кемгәдер бирү, сату, аны үзеңнеке дип хуҗа булу, билгеле бер кешене бу милекнең иясе дип тану тыела.

ның алдына куя. Ләкин кунаклар бу иткә кагылмый. Ибраһим галәйһиссәләм шулчак мосафирларының фәрештә икәнлеген аңлый. Исхак галәйһиссәләм туачагы турында сөенечле хәбәр китергәнлекләрен белмәгәнгә күрә, куркуга төшә һәм: «Аллаһ газабына лаек берәр нәрсә булдымы? Әллә кавемемне һәлак итәргә килгәннәрме?» – кебек борчулы уйларга бата. Фәрештәме-түгелме икәнлекләренә ышану өчен кабат: «Ашамыйсызмыни?» – дип дәшә, тегеләр: «Без бушка ашамыйбыз!» – дип җавап бирә. Шуннан соң Ибраһим галәйһиссәләм башта «Бисмиллаһ», ә ахырда «Әлхәмдүлиллаһ», дип әйтә. Фәрештәләр: «Чын Хәлил, Аллаһның дусты!» – диләр. Аннары: «Курыкма, йә Ибраһим, без моннан Лут кавеменә китеп, аларны һәлак итәчәкбез!» – дип, Ибраһим галәйһиссәләмне тынычландыралар.

Шулай итеп, сәфәрләренең һәм ризыкка кагылмауларының сәбәбе ачыклана. Ибраһим галәйһиссәләмнең куркуы эреп югалгач, фәрештәләр Исхак галәйһиссәләм һәм Ягъкуб галәйһиссәләм турында сөенечле хәбәрне тапшыра.

Бу очрашуны Сара анабыз пәрдә артыннан тыңлый. Сара анабыз, бик әдәпле һәм оялчан булганлыктан, куллары белән йөзен каплый. Иренең һәм үзенең инде карт булуы сәбәпле, бу хәбәрне ишеткәч, гаҗәпкә кала. Фәрештәләр исә: «Син Аллаһның әмеренә һәм тәкъдиренә аптырыйсыңмы?» – диләр.

Ибраһим галәйһиссәләм, алынган хәбәргә сөенгән хәлдә, Лут кавеменең һәлак ителәчәгенә бик кайгыра, чөнки ул казаның мөэминнәргә кагылмаячагы турында әле белми. Әлеге газап кире кагылсын өчен, Аллаһка ялварырга тели. Фәрештәләр инде доганың файда китермәячәген һәм бу газапның бары кяферләргә генә җибәрелгәнен белдерә. Шуннан соң Ибраһим галәйһиссәләм тынычланып кала.

Бу вакыйга Коръәни-Кәримдә болай искә алына:

وَلَقَدْ جَاءَتْ رُسُلُنَا إِبْرَهِيمَ بِالْبُشْرَى قَالُوا سَلَامًا قَالَ سَلَامٌ فَمَا لَبِثَ أَنْ جَاءَ بِعِجْلٍ حَنِيذٍ

**«Безнең илчеләребез (фәрештәләр) Ибраһимга сөенеч хәбәр белән килделәр дә: "Сәлам!" – диделәр. Ул да: "(Сезгә дә) сәлам!" – диде һәм кыздырылган бозау китерергә ашыкты»** («Һуд», 69).

(Ибне Габбастан риваятькә күрә, Ибраһим янына Җәбраил һәм аның белән бергә тагын ике фәрештә килә. Риваятьтә әлеге ике фәрештәнең Микаил һәм Исрафил булганлыгы әйтелә).

فَلَمَّا رَأَى أَيْدِيَهُمْ لَا تَصِلُ إِلَيْهِ نَكِرَهُمْ وَأَوْجَسَ مِنْهُمْ خِيفَةً قَالُوا لَا تَخَفْ إِنَّا أُرْسِلْنَا
إِلَى قَوْمِ لُوطٍ. وَامْرَأَتُهُ قَآئِمَةٌ فَضَحِكَتْ فَبَشَّرْنَاهَا بِإِسْحق وَمِنْ وَرَاءِ إِسْحقَ يَعْقُوبَ.
قَالَتْ يَا وَيْلَتَى أَأَلِدُ وَأَنَا عَجُوزٌ وَهذَا بَعْلِي شَيْخًا إِنَّ هَذَا لَشَيْءٌ عَجِيبٌ. قَالُوا

أَتَعْجَبِينَ مِنْ أَمْرِ اللَّهِ رَحْمَتُ اللَّهِ وَبَرَكَاتُهُ عَلَيْكُمْ أَهْلَ الْبَيْتِ إِنَّهُ حَمِيدٌ مَجِيدٌ. فَلَمَّا ذَهَبَ عَنْ إِبْرَهِيمَ الرَّوْعُ وَجَاءَتْهُ الْبُشْرَى يُجَادِلُنَا فِي قَوْمِ لُوطٍ

**«Әмма (кунакларының) кулларын аңа (ризыкка) сузмаган хәлдә күргәч, ул (Ибраһим) аларны ятсынды һәм алардан курку хис итте. Алар: "Курыкма! Һичшиксез, без (фәрештәләр) Лут кавеменә җибәрелдек", – диделәр. Хатыны исә басып тора иде, бу сүзләрне ишеткәч, көлеп җибәрде. Без исә аны Исхак белән, Исхактан соң Ягъкуб белән сөендердек. Ул (Ибраһимнең хатыны) әйтте: "Ни үкенеч миңа (булмас нәрсә)! Мин тудырачакмынмы? Мин бит инде карчыкмын. Бу ирем дә – бер карт. Һичшиксез, бу – искитәрлек бер нәрсә!" (Фәрештәләр) әйттеләр: "Аллаһның әмеренә хәйран каласыңмы әллә? И, әһле бәйт! Аллаһның рәхмәте һәм бәрәкәтләре сезгә булсын! Һичшиксез, Ул – Мактауга лаеклы, Юмартлыгы бөек булучы. Ибраһимнән курку киткәч һәм аңа сөенечле хәбәр килгәч, ул Лут кавеме хакында Безнең белән сүз көрәштерергә тотынды"»** («Һуд», 70–74).

Хәзрәти Ибраһим, Аллаһны инкяр итүчеләргә киләчәк гомуми һәлакәт һәм газапка Лут галәйһиссәләм белән Аңа ияручеләрнең дә тарыячагыннан курка, шунлыктан, ул газап кире алынсын өчен, Аллаһка бик үтенеп ялвара.

إِنَّ إِبْرَهِيمَ لَحَلِيمٌ أَوَّاهٌ مُنِيبٌ

**«Һичшиксез, Ибраһим һич ашыкмаган, күп аһ орган (башкалар өчен йөрәге янган) һәм (тулысынча Аллаһка) юнәлгән бер кеше иде»** («Һуд», 75).

Бу аяти кәримәдә Ибраһим галәйһиссәләмнең өч мөһим сыйфаты телгә алына:

Хилм – бик сабыр итү, хаталанган затлардан шундук үч алмыйча, сабырлык һәм түземлек күрсәтү дигән сүз.

Әүваһ сыйфаты, бик еш «аһ-ваһ» дип, бәндәләрнең начар хәлләренә һәм аяныч язмышларына бик кайгыруны белдерә.

Мөниб – Аллаһка ихлас юнәлгән, Аңа таба борылган дигән сүз. Хәзрәти Ибраһим бөтен эшләрендә дә Җәнабел-Хакка мөрәҗәгать итә, Аңа таяна.

Ибраһим галәйһиссәләм элегрәк күккә күтәрелгән чакта, Аллаһка каршы килгән имансызлар өчен бәддогалары сәбәпле илаһи кисәтү алуы нәтиҗәсендә, хәзер йөрәге бәндәләргә карата бик зур мәрхәмәтлелек белән тулган була. Шунлыктан, Лут кавеменә килергә тиешле газап бетерелсен өчен, Хак Тәгаләгә ялвара. Ләкин Лут кавеме Аллаһның рәхмәтенә тулысынча артын куя һәм шул дәрәҗәдә азгынлыкка бата ки, газап инде котылгысыз була, чөнки алар газап килүен үҗәтләнеп сорыйлар, шуңа күрә үзләренең әшәкелекләрен һич

туктатмыйлар. Хәтта үз араларында пакь, гөнаһсыз бәндәләрнең булуын да теләмиләр; «Пакь, игелекле кешеләр бездән китсен!» – дип, андыйларны куалар. Әнә шуңа күрә Китапта әйтелә:

يَا إِبْرَهِيمُ أَعْرِضْ عَنْ هَذَا إِنَّهُ قَدْ جَاءَ أَمْرُ رَبِّكَ وَإِنَّهُمْ آتِيهِمْ عَذَابٌ غَيْرُ مَرْدُودٍ

**«(Фәрештәләр әйттеләр:) “И, Ибраһим! Моннан ваз кич. Һичшиксез, Раббыңның (газап турында) әмере килде инде. Аларга (кяферләргә) котылгысыз бер газап киләчәк инде!”»** («Һуд», 76).

Бу вакыйганың мөһимлеге аркасында, ул «Зарият» сүрәсенең 24–30 нчы аятьләрендә башка бер стильдә кабат искә алына.

Ибраһим галәйһиссәләмнең аермалы тагын бер сыйфаты – кунакчыллык була. Ул килгән-киткән һәркемне ашатып-эчертеп, сыйлап җибәрә. Шуңа да «Әбул-Әдьяф – кунаклар атасы» дигән кушамат та бирелә (Ибне Сәгъд, «Табакат», I, 47). Ул кунакларны бик яратучы, бик сыйлаучы, искиткеч юмарт һәм хөрмәтле пәйгамбәр була. Хәтта кунак килмәгән көннәрдә юлларга чыгып, мосафирлар эзли һәм шул юлдан узган мосафир кешеләрне, сыйлар өчен, өенә алып кайта торган була.

Кунакчыллык – пәйгамбәрлек сыйфаты. Ашау-эчүдә чама белүгә игътибарлылык таләп ителсә дә, кунак сыйлаганда һәм кунакта ашаган ризыкта исраф юк. Ләкин сыйлауның һәм кунакка чакыруның дөнья һәм нәфес мәнфәгатьләреннән ераклыгы һәм Аллаһ өчен башкарылуы шарт.

### Ибраһим галәйһиссәләмнең Хәзрәти Исмәгыйльне зиярәт кылуы

Исмәгыйль галәйһиссәләм җүрһүмиләр кабиләсеннән бер кызга өйләнә. Бу кабилә аны бик ярата, хөрмәт итә. Хәзрәти Исмәгыйль алардан гарәп телен өйрәнә. Әнисе Һаҗәр анабыз туксан тугыз яшендә бакыйлыкка күчә һәм Кәгъбә янындагы Хижр үзәнлегенә җирләнә.

Хәдис-шәрифтә Ибраһим галәйһиссәләмнең улы Исмәгыйль галәйһиссәләмне зиярәт кылуы түбәндәгечә сурәтләнә:

Исмәгыйль галәйһиссәләм өйләнгәч, Ибраһим галәйһиссәләм улын күрергә килә. Әмма Исмәгыйль галәйһиссәләм өйдә булмый. Ата кеше улы турында аның хатыныннан сорый: «Ризык табу өчен чыгып китте», – дип җавап бирә җәмәгате.

Аннары Ибраһим галәйһиссәләм: «Тормышыгыз, хәл-әхвәлегез ничегрәк?» – дип сораша. Хәзрәти Исмәгыйльнең хатыны җавабында: «Бик кысынкылыкта яшибез, хәлебез бик авыр!» – ди. Ибраһим галәйһиссәләм: «Ирең өйгә кайткач, миннән сәлам әйт, ишегенең бусагасын алыштырсын!» – ди.

Исмәгыйль галәйһиссәләм кайткач, әтисе килеп киткәнен өй эчендәге хуш истән аңлый да: «Йортыбызга берәрсе килдеме әллә?» – дип сорый. Хатыны: «Әйе, фәлән-фәлән кыяфәтле өлкән кеше килде. Миннән сине сорады, әйттем. Тормышыбыз белән кызыксынды, мин исә бик кысынкылыкта, мохтаҗлыкта икәнлегебезне сөйләдем», – ди. Шуннан соң Исмәгыйль галәйһиссәләм: «Берәр нәрсә васыять итеп, ни дә булса әйтергә кушмадымы?» – дип сорый. «Сиңа сәлам тапшырырга һәм “ишегенең бусагасын алыштырсын!” дип әйтергә кушты», – ди хатыны.

Бу сүзләрдә яшеренгән мәгънәне аңлаган Исмәгыйль галәйһиссәләм җәмәгатенә: «Ул килгән кеше – минем өлкән яшьтәге атам. Миңа синнән аерылырга кушкан. Инде син үз гаиләңнең йортына кайтып китә аласың!» – ди дә өйдән чыгып китә. Ул җүрһүмиләр кабиләсеннән башка бер хатынга өйләнә.

Җәнабел-Хак билгеләгән күпмедер вакыттан соң, Ибраһим галәйһиссәләм янә улы янына килә, ләкин бу юлы да Исмәгыйль галәйһиссәләмне өйдә туры китерми. Ул Исмәгыйль галәйһиссәләмнең яңа өйләнгән хатыны янына барып, ире хакында сораша. Хатын: «Көндәлек ризыгыбызны кайгыртып йөри», – ди.

Ибраһим галәйһиссәләм: «Ни хәлдә яшисез, тормышларыгыз яхшымы соң?» – дип кызыксына. «Әлхәмдүлиллаһ, без бәхетле, тормышыбыз мул», – дип, хатын Аллаһка хәмед-сәнә әйтә. Ибраһим галәйһиссәләм: «Ни ашыйсыз, ни эчәсез?» – дип сорый. Хатын: «Ит ашыйбыз, су эчәбез», – ди. Ибраһим галәйһиссәләм: «Йә, Раббы! Боларның итләрен-суларын мөбарәк кыл! Муллык-бәрәкәт насыйп ит!» – дип дога кыла. Аннары ул Исмәгыйль галәйһиссәләмнең җәмәгатенә: «Ирең кайткач, сәлам әйт; ишегенең бусагасын саклап, кадерләп тотсын!» – ди.

Исмәгыйль галәйһиссәләм кайткач, янә өй эчендә тоеп алган хуш истән әтисенең килгәнен аңлый һәм хатыныннан: «Безгә берәрсе килдеме әллә?» – дип сорый. Җәмәгате: «Әйе, нурлы йөзле бер карт килде», – дип, Ибраһим галәйһиссәләмне мактап искә ала. Аннары сүзен дәвам итә. – Сине сорады. Мин “ризыгыбызны кайгыртып йөри”, дидем. “Көнкүрешегез ни хәлдә?” диде. Мин “мул һәм бәхетле яшибез”, дидем». Исмәгыйль галәйһиссәләм: «Ул берәр нәрсә тапшырдымы?» – дип сорый. Хатыны әйтә: «Әйе, ул мөхтәрәм карт сиңа сәлам әйтте. “Ишегенең бусагасын саклап тотсын!” дип кушты», – ди.

Шуннан соң Исмәгыйль галәйһиссәләм: «Ул атам булган. Ә син –йортыбызның хөрмәтле бусагасы. Әтием сине кадерләп яшәргә, сиңа карата яхшы мөгамәләдә булырга кушкан», – ди (Бохари, «Әнбия», 9).

Бу кыйссадан аңлашылганча, шөкер итү нигъмәтнең артуына һәм саклануына бер нигез була. Нигъмәтләрне аз дип санап зарлану исә – рәхмәтсезлек дигән сүз. Моның нәтиҗәсе – нигъмәтнең азаюы, ярлылык һәм үкенеч.

**Кәгъбәне төзү**

Күп кенә еллар узгач, Ибраһим галәйһиссәләм Мәккәгә кайта. Исмәгыйль галәйһиссәләм белән кочаклашып, сагышларын басалар. Хәзрәти Ибраһим улына: «Раббым бер йорт салырга әмер бирде. Син миңа ярдәм итәрсең!» – ди.

Исмәгыйль галәйһиссәләм һәм Җәбраил галәйһиссәләм таш ташый; Ибраһим галәйһиссәләм йортның диварларын тезә. Ибраһим макамы дип аталган урындагы Ибраһим галәйһиссәләмнең аяк эзе калган мәрмәр таш Кәгъбәнең стеналарын күтәргәндә үзенә күрә лифт вазифасын башкара.

Аяти кәримәдә:

وَإِذْ يَرْفَعُ إِبْرٰهِيمُ الْقَوَاعِدَ مِنَ الْبَيْتِ وَإِسْماعِيلُ رَبَّنَا تَقَبَّلْ مِنَّا إِنَّكَ أَنْتَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ

**«Вакытында Ибраһим белән Исмәгыйль Бәйттән (Бәйтуллаһтан) калган нигезләрне күтәрделәр (һәм болай диләр иде): “И, Раббыбыз! Бездән (моны) кабул ит, һичшиксез, Син – Ишетүче, Белүче!”»** – дип әйтелә. («әл-Бәкара», 127).

Кәгъбәне төзү турындагы риваятьләргә күрә, Хәзрәти Адәм белән Хәүва җәннәттән чыгарылгач, Гарәфәттә очраша һәм бергә көнбатышка таба китәләр. Алар хәзер Кәгъбә булган җиргә килә. Шулвакытта Адәм галәйһиссәләм әлеге очрашуга шөкер итү өчен, Раббысына гыйбадәт кылырга тели һәм җәннәттә чагында тирә-ягында тәваф кылып гыйбадәтләрен башкарган нур баганасының үзенә кабат бирелүен сорый. Әнә шул нур баганасы пәйда була һәм Хәзрәти Адәм, аның тирәсендә тәваф кылып, Аллаһка гыйбадәтен үти. Бу нур баганасы Хәзрәти Шит галәйһиссәләм чорында юкка чыга, аның урынында бер кара таш кала. Шуннан соң Хәзрәти Шит аның урынына шул кара таш кебек дүртпочмаклы итеп таштан бина сала һәм кара ташны шул бинаның бер почмагына урнаштыра. Бүген безгә Хаҗәри Әсвәд буларак билгеле кара таш әнә шул инде. Соңыннан, Нух туфаны заманында, бу бина бик озак вакыт ком астында кала. Аллаһ әмеренә буйсынып, Хәзрәти Ибраһим Кәгъбә булган җиргә килә, улы Исмәгыйль галәйһиссәләмне анасы белән бергә шунда урнаштыра. Соңыннан Исмәгыйль галәйһиссәләм белән бергә, Аллаһның әмеренә ярашлы рәвештә, Кәгъбә булырга тиешле җирне казый. Хәзрәти Шит салган бинаның нигезләрен табып, шул нигезгә бүгенге Кәгъбәне төзи. Аятьтәге «Бәйтуллаһтан калган нигезләрне күтәрделәр», җөмләсе әнә шул хакта хәбәр итә.

Ибраһим галәйһиссәләм, кешеләрнең Кәгъбәне тәваф кыла башлауларына бер билге булсын өчен, Хаҗәри Әсвәдне Кәгъбәнең бер почмагына куя. Риваятькә күрә, әлеге кара таш җәннәттән чыгарылган чакта, кардан да аграк булган, тик бәндәләрнең гөнаһлары аның каралуына китергән (Ибне Ханбәл, I, 307). Җаһилият һәм ислам чорларында бер-бер артлы кабынып торган янгыннар аны тагын да ныграк каралта.

Кәгъбәнең төзелеше тәмамлангач, Хәзрәти Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимәс-сәләм, Аллаһка болай дип дога кылалар:

رَبَّنَا وَاجْعَلْنَا مُسْلِمَيْنِ لَكَ وَمِنْ ذُرِّيَّتِنَا أُمَّةً مُسْلِمَةً لَكَ وَأَرِنَا مَنَاسِكَنَا وَتُبْ عَلَيْنَآ إِنَّكَ أَنْتَ التَّوَّابُ الرَّحِيمُ. رَبَّنَا وَابْعَثْ فِيهِمْ رَسُولًا مِنْهُمْ يَتْلُوا عَلَيْهِمْ آيَاتِكَ وَيُعَلِّمُهُمُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَيُزَكِّيهِمْ إِنَّكَ أَنْتَ العَزِيزُ الحَكِيمُ

**«И, Раббыбыз! Безне Сиңа буйсынучылардан ит, нәселебездән – Сиңа гына итагать иткән бер өммәтне (чыгар), безгә гыйбадәт урыннарыбызны күрсәт һәм тәүбәбезне кабул әйлә! Һичшиксез, Син – Тәүбәләрне кабул итүче, Рәхимле. И, Раббыбыз! Алар арасыннан Синең аятьләреңне укыячак, китапны һәм хикмәтне өйрәтәчәк һәм аларны (нәфесләрен) сафландырачак бер пәйгамбәр җибәр! Һичшиксез, Син – Бөек, (һәрнәрсәне тиешенчә башкаручы) Хикмәт иясе!»** («әл-Бәкара», 128–129).

Аятьтә искә алынган дога белән бәйле рәвештә, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «*Мин – атам Ибраһимнең догасы, туганым Гайсәнең сөенечле хәбәре һәм анам Әминәнең төшемен*», – дип әйткән (Әхмәд ибне Ханбәл, V, 262; Хаким, «Мүстәдрәк», II, 453).

Шул рәвешле ике җиһан кояшы – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм пакь нәсел шәҗәрәсе менә мондый була:

1. Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм;
2. Габдуллаһ;
3. Габделмотталиб (Шәйбәтүлхәмд дип тә йөртелә);
4. Һашим;
5. Габде Мәннаф (чын исеме – Мугыйрә);
6. Кусай (Зәйд дип тә йөртелә);
7. Хәким (Киләб);
8. Мүррәһ;
9. Кәгъб;
10. Лүәйй;
11. Галиб;
12. Фиһр (Корәеш);
13. Малик;
14. Надр;

15. Кинанә;

16. Хузәймә;

17. Мүдрикә;

18. Ильяс;

19. Мудар;

20. Низар;

21. Мәгад;

22. Гаднән.

Аллаһ Рәсүленең пакь шәҗәрә чылбыры Гаднәнгә кадәр санала. Ә Гаднән Исмәгыйль галәйһиссәләм нәселеннән килә. Бу ике зат арасында узган вакыт билгеле түгел.

Кыскасы, Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләмнең нәселеннән пәйгамбәрләр килүе һәм, аерым алганда, Галәмнәр горурлыгы булган Яшәеш нуры Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм белән хөрмәтләнүе, Хәзрәти Ибраһимнең пәйгамбәрләр тарихындагы гайре үзенчәлекле һәм мөһим урынын күрсәтә. Кәгъбә һәм хаҗ рөкеннәрендә Ибраһим галәйһиссәләмгә кагылышлы истәлекләр кыямәткәчә сакланачак. Шулай ук миллионнарча мөселман һәр көн биш вакыт намазның әттәхиятендә Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйткәндә, Аллаһның рәхмәте белән Ибраһим галәйһиссәләмгә бирелгән сәлам-салаватны да искә алалар.

Әбү Мөхәммәд Кәгъб ибне Ужрә радыйаллаһу ганһе болай дип тапшыра:

Беркөнне Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм яныбызга килде. Аннан: «Йә, Рәсүлүллаһ! Сиңа ничек сәлам бирергә икәнен өйрәндек, ә сиңа ничек салават әйтергә тиешбез?» – дип сорадык. Ул болай диде:

اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى (إِبْرَاهِيمَ)
وَعَلَ آلِ إِبْرهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ.اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ كَمَا
بَارَكْتَ عَلَى إِبْرَهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْرَهِيمَ اِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ

*«“Аллаһым! (Ибраһимгә һәм) нәселенә сәлам-салават ирештергән кебек Мөхәммәдкә һәм аның нәселенә дә сәлам-салават ирештер. Һичшиксез, Син –мактауга лаек һәм Бөек. Аллаһым! (Ибраһимгә һәм) нәселенә бәрәкәт ирештергән кебек Мөхәммәдкә һәм аның нәселенә дә бәрәкәт насыйп ит. Һичшиксез, Син – мактауга лаек һәм Бөек!” – дип әйтегез»* (Бохари, «Дәгъват», 32; Тирмизи, «Витр», 20; Ибне Мәҗә, «Икамә», 25).

### Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимәс-сәләмнең тәүге хаҗы һәм кешеләрне хаҗга чакыруы

Кәгъбә төзелеше тәмамлангач, Җәбраил галәйһиссәләм Хәзрәти Ибраһим янына килеп: «Аны тәваф кыл!» – ди. Ата белән угыл һәр тапкырында (шәветтә[85]), Кара ташны сәламләү шарты белән, Кәгъбәне тәваф кыла. Ибраһим макамының артында ике рәкәгать намаз укыйлар. Җәбраил галәйһиссәләмнең җитәкчелегендә хаҗның башка рөкеннәрен дә үтиләр. Аннары Җәбраил галәйһиссәләм Хәзрәти Ибраһимгә кешеләрне хаҗга өндәргә куша. Хәзрәти Ибраһим моны ничек башкарачагы турында сорагач:

«“Әй, кешеләр, Раббыгызның чакыруына колак салыгыз!” – дип кычкырып әйт», – дип аңлата һәм моны өч тапкыр кабатлый.

Соңыннан Ибраһим галәйһиссәләм Аллаһ Тәгаләдән:

«Йә, Раббы, минем тавышым бөтен кешеләргә ничек ишетелә алыр?» – дип сорый.

Җәнабел-Хак:

«Син оран сал, аны кешеләргә ирештерү – Минеке», – дип белдерә.

Аяти кәримәдә бу хикмәт түбәндәгечә телгә алына:

وَأَذِّن فِي النَّاسِ بِالْحَجِّ يَأْتُوكَ رِجَالًا وَعَلَى كُلِّ ضَامِرٍ يَأْتِينَ مِنْ كُلِّ فَجٍّ عَمِيقٍ

**«(Әй, Ибраһим!) Кешеләр арасында хаҗны игълан ит, җәяү һәм һәр ерак юлдан килгән арык дөя өстендә сиңа килсеннәр»** («әл-Хаҗ», 27).

Шуннан соң Ибраһим галәйһиссәләм һәр ел Мәккәгә барып хаҗ кыла. Хәзрәти Ибраһимнән соң килгән пәйгамбәрләр һәм аларның мөэмин өммәтләре дә Мәккәгә килеп хаҗ гыйбадәтен үтиләр. Өммәтләре һәлак булган пәйгамбәрләр Мәккәгә килеп, соңгы сәгатьләре сукканчы, гомерләрен шунда гыйбадәт кылып уздыралар.

### Ибраһим галәйһиссәләмнең дога-ялварулары

Ибраһим галәйһиссәләм – Коръәни-Кәримдә догасы иң күп искә алынган пәйгамбәр. Аның һәртөрле уңайдан Бөек Раббысына ихлас догада ялварганлыгы аңлашыла. Коръәни-Кәримдә, югарыда искә алынганнардан кала, Хәзрәти Ибраһимнең мондый догаларын күрәбез:

رَبَّنَا إِنَّكَ تَعْلَمُ مَا نُخْفِي وَمَا نُعْلِنُ وَمَا يَخْفَى عَلَى اللهِ مِنْ شَيْءٍ فِي الْأَرْضِ وَلَا فِي السَّمَاء

85. Шәвет – Хаҗәри Әсвәдтән (Кара таштан) башлап, Кәгъбә тирәли янә Хаҗәри Әсвәд тарафына килеп чыгарлык итеп бер тапкыр урап чыгу.

**«И, Раббыбыз! Һичшиксез, Син яшергән нәрсәләребезне дә, ачык нәрсәләребезне дә беләсең. Җирдә дә, күктә дә бернәрсә дә Аллаһтан яшерен калмый»** («Ибраһим», 38).

الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي وَهَبَ لِي عَلَى الْكِبَرِ إِسْمٰعِيلَ وَإِسْحٰقَ إِنَّ رَبِّي لَسَمِيعُ الدُّعَاءِ

**«Барча мактаулар картайган көнемдә миңа Исмәгыйльне һәм Исхакны биргән Аллаһка. Һичшиксез, минем Раббым – doганы ишетүче»** («Ибраһим», 39).

رَبِّ اجْعَلْنِي مُقِيمَ الصَّلٰوةِ وَمِنْ ذُرِّيَّتِي رَبَّنَا وَتَقَبَّلْ دُعَاءِ

**«И, Раббым! Мине намаз үтәүче (кыл) һәм минем нәселемне дә. И, Раббыбыз! Догамны кабул әйлә»** («Ибраһим», 40).

رَبَّنَا اغْفِرْ لِي وَلِوَالِدَيَّ وَلِلْمُؤْمِنِينَ يَوْمَ يَقُومُ الْحِسَابُ

**«И, Раббыбыз! Хисап булачак көнне мине дә, ата-анамны да, барча мөэминнәрне дә ярлыка!»** («Ибраһим», 41).

«Шугара» сүрәсендә исә Хәзрәти Ибраһимнең ихлас күңеленнән чыккан мондый үтенечен күрәбез:

رَبِّ هَبْ لِي حُكْمًا وَأَلْحِقْنِي بِالصَّالِحِينَ. وَاجْعَلْ لِي لِسَانَ صِدْقٍ فِي الْآخِرِينَ. وَاجْعَلْنِي مِنْ وَرَثَةِ جَنَّةِ النَّعِيمِ. وَاغْفِرْ لِأَبِي إِنَّهُ كَانَ مِنَ الضَّالِّينَ. وَلَا تُخْزِنِي يَوْمَ يُبْعَثُونَ. يَوْمَ لَا يَنْفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ. إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ

**«И, Раббым! Миңа бер хөкем бир һәм мине изгеләргә куш! Соңгылар (өммәтләр) арасында мине яхшылык белән искә алсыннар. Мине нигъмәтләр белән тулы (нәгыйм) җәннәтнең мирасчыларыннан кыл. Атамны да ярлыка, чөнки ул адашкан кемсәләрдән булды. Мине алар (кешеләр) терелтеләчәк көнне оятка калдырма. Бер малның да, улларның да файда бирмәгән көнне. Мәгәр керсез күңел белән Аллаһка килүче булмаса гына!»** («әш-Шугара», 83–89).

Сәламәт йөрәк белән килүче зат, дигәндә, малларын хәерле урынга сарыф итүче, балаларына хакны һәм хакыйкатьне өйрәтүче, күңелен мал һәм балаларга артык бәйлелектән, дин мәсьәләсендә надан калудан, әдәпсезлектән һәм төрле начар сыйфатлардан пакь кылучы бәндә күздә тотыла.

Әбүл-Касыйм әл-Хаким фикеренчә, сәламәт йөрәкнең өч билгесе бар:

1. Һичкемне кыерсытмау, рәнҗетмәү;

2. Һичкемгә рәнҗемәү, үпкәләмәү;

3. Кемгәдер яхшылык эшләгәндә, аннан җавап көтмәү.

Һичкемне кыерсытмаган очракта, бәндә Аллаһ Тәгалә каршына хаклык һәм тәкъвалык белән, берәүгә дә рәнҗемәгән очракта тугрылык белән, кылганына әҗер сорамаган очракта исә ихласлыгы белән басачак.

**Хәзрәти Ибраһим нәсыйхәтләре**

Аллаһ Тәгалә Ибраһим галәйһиссәләмгә мондый вәхи иңдерә:

«Һичшиксез, син Минем дустым, Мин дә синең дустың. Сак бул, йөрәгеңне белеп торган вакытта, Мин анда үземнән башканы күрмим. Югыйсә Миңа карата мәхәббәтеңне өзәрмен, чөнки Мин үз мәхәббәтем өчен шундый затны сайлыйм ки, аны хәтта утта яндырсам да, барыбер йөрәге Миннән башка берәүгә хөрмәт күрсәтмәс һәм ул йөрәктә Миннән башка һичкем урын алмас. Миңа карата шундый мөнәсәбәттә булганда, Мин дә аның йөрәгенә сөюемне салырмын. Аңа рәхмәтем һәм әҗерләрем дәвам итәр. Хәтта аны үземә якын итәрмен».

Ибраһим галәйһиссәләм үзеннән үгет-нәсыйхәт сораганнарга мондый киңәш бирә:

«Кешеләрнең дөнья эшләре белән мәшгуль булганнарын күргән вакытта, сез исә ахирәт эшләре белән шөгыльләнегез. Алар күзгә бәрелеп торганнарны бизәү белән мәшгуль булса, сез исә күңелегезне матурлау белән шөгыльләнегез. Алар бакчаларын һәм сарайларын төзү белән мәшгуль булса, сез исә каберегезне (ахирәтегезне) ясау белән шөгыльләнегез. Кешеләр бер-берсенең гаеп-гөнаһларын тикшерү белән мәшгуль булса, сез исә үз гөнаһларыгызны карагыз».

Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм шулкадәр югары дәрәҗәле пәйгамбәр ки, Аның фазыйләтен кабул итмәгән һәм расламаган халык юк. Гарәп мөшрикләре үзләрен аның балалары һәм тарафдарлары булганлыкларын сөйләп, башкалардан өстенлекләрен күрсәтергә тырышалар. Мөшрикләр белән бергә яһүдиләр, нәсаралар һәм мөселманнар да аны хөрмәт итә һәм аның югары дәрәҗәсен таный. Галәмнең күпчелеге тарафыннан фазыйләтен һәм хөрмәтле дәрәҗәсен тану Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм хәтле һичкемгә насыйп булмый. Аяти кәримәдә мөселманнардан кала башкаларның аның турында фикер-бәяләмәләренә бәйле рәвештә болай дип әйтелә:

مَا كَانَ إِبْرٰهِيمُ يَهُودِيًّا وَلَا نَصْرَانِيًّا وَلٰكِنْ كَانَ حَنِيفًا مُسْلِمًا وَمَا كَانَ مِنَ الْمُشْرِكِينَ.

إِنَّ أَوْلَى النَّاسِ بِإِبْرٰهِيمَ لَلَّذِينَ اتَّبَعُوهُ وَهٰذَا النَّبِيُّ وَالَّذِينَ آمَنُوا وَاللّٰهُ وَلِيُّ الْمُؤْمِنِينَ

**«Ибраһим яһүди дә, нәсара да түгел иде. Вә ләкин ул хәниф бер мөселман иде. Ул мөшрикләрдән түгел иде. Һичшиксез, Ибраһимга иң якын кешеләр – аңа ияргәннәр, шушы Пәйгамбәр (Хәзрәти Мөхәммәд) һәм (Аңа) иман китергәннәр. Аллаһ исә – мөэминнәрнең вәлие»** («Әли Гыймран», 67–68).

Хәзрәти Әнәс радыйаллаһу ганһе мондый хәдисне риваять кыла:

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәләмгә бер кеше килә дә: «Әй, Хәйрүл-Бәриййә – йә Яратылганнарның иң хәерлесе», – дип мөрәҗәгать итә. Пәйгамбәребез галәйһис-саләтү вәс-сәләәм шундук катгый сүзен әйтә: *«Бу әйткәннәрең – Ибраһим галәйһиссәләмнең сыйфаты ул»* (Мөслим, «Фәдаил», 150).

***Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм***





хәзрәти

# Исмәгыйль

*галәйһиссәләм*

### *Ихласлыгы, тугрылыгы, буйсынучанлыгы һәм үзен Аллаһка багышлавы белән бер символга әйләнгән*

# ХӘЗРӘТИ ИСМӘГЫЙЛЬ

### *галәйһиссәләм*

Хәзрәти Исмәгыйль галәйһиссәләм – Коръәни-Кәримдә исеме искә алынган пәйгамбәрләрдән. Аны «Аллаһ корбаны» мәгънәсендәге «Зәбихуллаһ» дип тә атыйлар. Исмәгыйль галәйһиссәләм Йәмәннән килгән Җүрһүми кабиләсенең пәйгамбәре була. Исеме «Аллаһка итагать итүче» дигәнне белдерә. Ивритчәдә исеме – Исмуэль. Гарәпләр исә Исмәгыйль дип атый.

Хәзрәти Исмәгыйль җүрһүмиләрнең балалары белән үсә, җәядән атарга да шулардан өйрәнә. Егетлек чорына җиткәндә, бик оста укчы була, мәргәнлеге белән таныла. Әсләм кабиләсеннән бер төркем җәядән атып ярышканда, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, алар янына килеп:

*«Әй, Исмәгыйль угыллары! Ук атыгыз! Сезнең ата-бабагыз да өстә укчы иде»*, – дип әйтә (Бохари, «Әнбия», 9).

Әтисенең үлеменнән соң Исмәгыйль галәйһиссәләм Кәгъбә һәм хаҗ белән бәйле эшләрне алып баруын дәвам итә. Иң беренче булып Кәгъбәнең өстен яба. Аллаһ Тәгалә, пәйгамбәрлек йөкләп, аны Мәккәдә һәм аның якын-тирәсендәге Җүрһүми һәм Амалика белән Йәмән кабиләләренә, Мәгъриб һәм Хадрамәүт якларына пәйгамбәр итеп җибәрә. Хәзрәти Исмәгыйль аларны илле ел исламга өнди. Кайберләре иманга килә, кайберләре исә көферлегеннән ваз кичми. Ләкин иман китерүчеләр бик аз була. Исмәгыйль галәйһиссәләм сабырлык һәм үҗәтлек белән үз вазифасын башкаруны дәвам итә. Аяти кәримәдә болай дип әйтелә:

وَإِسْمعِيلَ وَإِدْرِيسَ وَذَا الْكِفْلِ كُلٌّ مِنَ الصَّابِرِينَ

**«(Хәбибем) Исмәгыйльне, Идрисне һәм Зүлкифлне дә (искә ал)! Аларның һәрберсе сабыр итүчеләрдән иде»** («әл-Әнбия», 85).

Хәзрәти Исмәгыйль вәгъдәсенә тугры калган, намаз һәм зәкятка өндәгән, Раббы катында Аның ризалыгына ирешкән пәйгамбәр була. Аның бу сыйфатлары аяти кәримәдә дә раслана:

وَاذْكُرْ فِي الْكِتَابِ إِسْمعِيلَ إِنَّهُ كَانَ صَادِقَ الْوَعْدِ وَكَانَ رَسُولًا نَبِيًّا.
وَكَانَ يَأْمُرُ أَهْلَهُ بِالصَّلوةِ وَالزَّكوةِ وَكَانَ عِنْدَ رَبِّهِ مَرْضِيًّا

**«(Хәбибем) Китапта Исмәгыйльне дә искә ал. Һичшиксез, ул сүзенә бик тугры иде. Һәм бер рәсүл һәм бер нәби иде. Ул халкына (һәм өммәтенә) намазны һәм зәкятны әмер итә иде. Раббысы аңардан разый иде (ризалыгына лаек булган зат иде)»** («Мәрьям», 54–55).

**Могҗизалары**

1. Энәле чүп үләннәре үскән урынны яшеллеккә күмә.

2. Кысыр сарыклар аның догасы бәрәкәтендә сөт бирә.

3. Сарыкларының йоннары ефәк кебек нәфисләнә.

4. Аның догасы белән янындагы комнар онга әйләнә.

5. Зәмзәм чишмәсе аның ярдәме, аның катнашы белән бәреп чыгып, кыяматкә кадәр сакланачак.

Үзенчәлекле, аерып торган сыйфаты – сабырлык, киң күңеллелек һәм буйсынучанлык.

Галәйһиссәләм…



ХӘЗРӘТИ

# Исхак

*галәйһиссәләм*

*Нәселеннән Бәни Исраил пәйгамбәрләре чыккан*

# ХӘЗРӘТИ ИСХАК

***галәйһиссәләм***

Исхак галәйһиссәләм – Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләмнең Сарадан туган улы. Тарих китапларында тасвирланган килеш-кыяфәте мондыйрак: «Озын буйлы, кара күзле, бераз карасу тәнле, матур йөзле. Чәче-сакалы – ап-ак. Сүзгә оста. Тормыш юлы һәм килеш-килбәте атасы Ибраһим галәйһиссәләмнекенә охшаган» (Хаким, «Мүстәдрәк», II, 607).

Коръәни-Кәримдә Исхак галәйһиссәләм мактап телгә алына:

وَاذْكُرْ عِبَادَنَا إِبْرَاهِيمَ وَإِسْحٰقَ وَيَعْقُوبَ أُولِي الْأَيْدِي وَالْأَبْصَارِ إِنَّا أَخْلَصْنَاهُم بِخَالِصَةٍ ذِكْرَى الدَّارِ وَإِنَّهُمْ عِنْدَنَا لَمِنَ الْمُصْطَفَيْنَ الْأَخْيَارِ

**«(Әй, Хәбибем!) Көч һәм зирәклек ияләре булган колларыбыз Ибраһимне, Исхакны һәм Ягъкубны да искә ал. Һичшиксез, Без аларны ихласлык белән (ахирәт) йортын истә тотканнары өчен сайлап алдык. Һичшиксез, алар Безнең хозурыбызда сайлап алынган колларыбыздан, иң яхшылардан»** («Сад», 45–47).

Әтисе үлгәч, Хәзрәти Исхак галәйһиссәләм Димәшкъ һәм Палестина халыкларына пәйгамбәр итеп юллана, Аллаһ Тәгалә аны сайлап алынган, хәерле бәндәгә әйләндерә. Аяти кәримәләрдә:

وَبَشَّرْنَاهُ بِإِسْحٰقَ نَبِيًّا مِنَ الصَّالِحِينَ. وَبَارَكْنَا عَلَيْهِ وَعَلَى إِسْحٰقَ وَمِنْ ذُرِّيَّتِهِمَا مُحْسِنٌ وَظَالِمٌ لِنَفْسِهِ مُبِينٌ

**«Изгеләрдән бер пәйгамбәр булачак Исхак белән Без аны (Ибраһимне) сөендердек. Аңа да, Исхакка да бәрәкәт яудырдык. Әмма икесенең нәселеннән дә игелек кылган да, үз-үзенә ап-ачык золым иткән дә бар»**, – дип әйтелә («әс-Саффат», 112–113).

Олыгайгач, Исхак галәйһиссәләмнең күзләре зәгыйфьләнә, ул тәмам сукырая. Ике улы – Ягъкуб һәм Ийс (Әсав) игезәк булып туалар. Исхак галәйһиссәләм гомернең ахырына таба ике улына багышлап аерым-аерым дога укый. Ягъкубның нәселеннән пәйгамбәрләр чыксын; Ийснең балалары-оныклары күп булсын, нәселеннән хөкемдарлар һәм солтаннар тусын өчен, Җәнабел-Хакка ялвара.

**Төрле риваятьләргә күрә, Исхак галәйһиссәләмнең могҗизалары**

Кавеме аңа: «Хайваннар синең пәйгамбәр икәнлегеңне расламаса, без сиңа ышанмабыз!» – диләр.

Исхак галәйһиссәләм исә җанварларга: «Әй, хайваннар! Минем кем икәнлегемне әйтегез!» – дип боера. Төлке: «Аллаһның пәйгамбәресең!» – ди.

Җәйлән: «Хәлилуллаһның улы син!» – ди.

Кәҗә: «Аллаһның пәйгамбәресең! Сиңа иман китермәгән җәһәннәмгә олагыр!» – ди.

Иерусалимдә дингә өндәгән чакта, Исхак галәйһиссәләмгә: «Әгәр шушы тауны күчерә алсаң, сиңа иман китерербез!» – дип әйтәләр.

Тау бик куәтле тетрәп куя һәм Иерусалим халкы иманга килә.

Кавемен иманга чакырганда, берәү сыер тиреләре алып килә дә: «Боларны терелт!» – ди.

Исхак галәйһиссәләм тиреләрнең эченә ком тутырып, дога кыла. Тиреләрнең барысы да җанлана.

Тагын бер могҗизасы – ул кагылган бөтен сарыклар да бәрән китерә.

Хәзрәти Исхак, риваятькә күрә, йөз алтмыш яшьләр тирәсендә хәзерге Палестина урнашкан өлкәдә, Иерусалимга якын бер җирдә вафат була, әтисе Ибраһим галәйһиссәләмнең кабере янына җирләнә (Ибне Әсир, «әл-Камил», I, 127).

Галәйһиссәләм!..

# АЛЛАҺКА ТӘВӘККӘЛ КЫЛУ, БУЙСЫНУЧАНЛЫК ҺӘМ ХАҖ

Аллаһка тәвәккәл кылу, буйсынучанлык һәм хаҗ сүзләре искә алынганда, Ибраһим галәйһиссәләм белән Исмәгыйль галәйһиссәләм хәтергә килә, чөнки хаҗ, аларның ихласлыклары нәтиҗәсендә, кыямәткәчә кабатланып, башкарылып торачак изге гамәлгә әйләнә.

«Тәвәккәл кылу» гыйбарәсенең сүзлек мәгънәсе – «таяну, ышану, вәкил итеп тоту һәм вәкилгә таяну, ышану». Тасаувыфта исә бу гыйбарә күңеле Аллаһ белән тулган затның бары тик Аңа гына таянуын һәм Аңа гына сыенуын белдерә.

Җәнабел-Хак Муса галәйһиссәләмгә кулындагы таягы турында сорау бирә, аннары: «Аны кулыңнан ташла!» – дип боера, чөнки таяк аның Аллаһка гына таянуына күләгә төшерә, моны киметеп күрсәтә.[86]

Аяти кәримәләрдә болай диелә:

وَعَلَى اللّٰهِ فَلْيَتَوَكَّلِ الْمُؤْمِنُونَ

**«…Мөэминнәр Аллаһка гына тәвәккәл итсен!»** («Ибраһим», 11; «әт-Тәүбә», 51).

وَعَلَى اللّٰهِ فَتَوَكَّلُوا اِنْ كُنْتُمْ مُؤْمِنِينَ

**«…Әгәр ышанган кешеләр булсагыз, Аллаһка гына тәвәккәл итегез!»** («әл-Маидә», 23).

وَمَنْ يَتَوَكَّلْ عَلَى اللّٰهِ فَهُوَ حَسْبُهُ

**«…Кем дә кем Аллаһка тәвәккәл кыла, аңа Ул җитә!..»** («әт-Талак», 3).

Хәдис-шәрифтә исә:

*«Әгәр сез Аллаһка тиешенчә тәвәккәл кыла алсагыз, иртән карыннары ач килеш китеп, кичен тук булып кайткан кошлар ризыкланган кебек ризыкландырылырсыз!»* – дип белдерелә (Тирмизи, «Зүһд», 33; Ибне Мәҗә, «Зүһд», 14).

86. Карагыз: Разый, «Тәфсири Кәбир», XXII, 23–25.

Тәвәккәл кылу – чара-ысулларны, теләк-омтылышларны читкә этәрү түгел, киресенчә, аларга таянып, Аллаһның кодрәтенә сыену ул. Аллаһ Тәгалә болай дип боера:

وَشَاوِرْهُمْ فِي الْأَمْرِ فَإِذَا عَزَمْتَ فَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُتَوَكِّلِينَ

**«...(Бу эш турында вәхи килмәгән) эшләрдә алар (мөэминнәр) белән киңәш. Әмма карарга килсәң, шунда ук Аллаһка тапшыр!»** («Әли Гыймран», 159).

Җәнабел-Хак – бөтен сәбәпләрне барлыкка китерүче. Ул, үзе теләгән вакытта, хәтта гамәлдәге табигать кануннарына каршы килгән хөкемнәрен дә чыгара ала. Мәсәлән, Хәзрәти Адәмне – туфрактан, аның хатыны Хәуваны исә аның тәненнән яралта. Кавышу-өйләнешү канунына каршы килеп, Хәзрәти Гайсәне Хәзрәти Мәрьямнән атасыз рәвештә дөньяга китерә. Хәзрәти Ибраһимне Нәмруд утында янудан саклап кала, Ул утка турыдан-туры: «И, ут! Ибраһим өчен салкынлык һәм тынычлык бул!» – дип әмер бирә. Хәзрәти Мусага таяк белән бер сугу бәрабәренә диңгез аша каршы ярга юл ача, шулай итеп могҗизалы рәвештә аны һәм кавемен Фиргавен золымыннан коткара. Хәзрәти Гозәерне йөзьеллык мәрткә җибәреп үтерә, шулкадәр вакыт эчендә аның янындагы ризыкны бозылудан саклый, үлгән ишәген исә, сөякләренә итләрен кире кайтарып, кабат терелтә. Әсхәбе Кәһфне (Мәгарә әһелләрен) өч йөз елдан артык вакыт сусыз-азыксыз килеш, йоклаган хәлдә яшәтеп тора.

Халикъ Тәгалә үзе теләгән нәрсәгә, үзе теләгән затка су өстеннән йөрергә мөмкинлек бирер, канатсыз килеш һавада очырыр. Күз күремен бетереп, йөрәкне күзләргә әйләндерер һәм гадәти күз белән күрелмәгән галәмнәрне күрсәтер. Ләкин шуңа игътибар бирү зарур: утның Хәзрәти Ибраһимне яндырмавын мисал итеп, берәүнең үзенә карата да шундый могҗиза көтүе чикләрне, мөмкинлекләрне белмәү булачак һәм хәсрәткә, үкенечкә китерәчәк.

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ бу мәсьәләне:

«Аллаһ юлында утка керергә туры килергә мөмкин, ләкин утка ташланганчы, үзеңдә Ибраһимгә хас сыйфатлар бармы-юкмы икәнен кара! Чөнки ут сине түгел, ә Ибраһимнәрне таный һәм яндырмый!» – дип аңлата.

Кыскасы, берәүнең үзен чын камил, бик югары дәрәҗәгә ия затлар белән чагыштыруы куркыныч нәтиҗәгә китерәчәк наданлык булып тора. Асылда, без кулыбыздан килгәнчә кирәкле чарасын күреп, нәтиҗәсен Аллаһка тапшырып, Аңа сыенырга тиешбез. Чөнки чарасыз-нигезсез Аллаһка гына өмет итүне Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дә тыйган:

Бер бәдәви: «Йә, Рәсүлүллаһ! Дөямне чүлдә калдырып, Аллаһка тапшырам!» – дигән.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә аңа:

*«Дөяңне бәйлә дә шуннан соң Аллаһка тапшыр!»* – дип кисәтә (Тирмизи, «Кыямәт», 60).

Хәлифә Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе хәрби поход вакытында ислам гаскәренең йогышлы чир таралган бер төбәккә керүенә каршы чыга. Армия командиры Әбу Гобәйдә ибне Җәррaһ радыйаллаһу ганһе: «Йә, хәлифә! Аллаһ билгеләгән язмыштан качасыңмыни?» – ди. Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе: «Әйе, без Аллаһның бер тәкъдиреннән сакланып, башка тәкъдиренә сыенабыз!» – дип җавап бирә (Бохари, «Тыйб», 30). Чөнки хәдис-шәрифтә: «Саулар янына авыруларны йөртмәгез!» – дип, йогышлы чирләрдән сакланырга кушылган (Бохари, «Тыйб», 53; Мөслим, «Сәлам», 104).

Аллаһ мөэминне һәр ике дөньяда ярдәменнән ташламый. Кем дә кем Аңа тәвәккәл кылса, Аллаһ шуны яклый. Шәхси, иҗтимагый тынычлык һәм бәхет – Аллаһка юнәлүдә, Аннан ярдәм сораүда, Аңа тәвәккәл кылуда.

«Буйсынучанлык» дигән сүз бил бөгү, үз башыңа килгән вакыйгаларны каршылыксыз-нисез кабул итү, куркынычтан котылу дигәнне белдерә. Буйсыну, күңел гамәле булып, Аллаһ тарафыннан анықланган мәсьәләләргә мөнәсәбәтле төрле шик-шөбһәләрдән, илаһи хөкемнәргә каршы килгән нәфес омтылышларыннан, ихласлык белән бәйләнеше булмаган теләкләрдән, илаһи тәкъдиргә һәм ислам шәригатенә ризасызлык чиреннән котылу дигән сүз.

Буйсынучанлык – ышану, иман дәрәҗәсендә күңел белән таяну, сыену эзләү хисләре бәрабәренә чынга аша ала. Бу исә таяныч вазифасын башкаручының һәр тарафтан ышанычлы зат сыйфатына ия булуын таләп итә. Димәк, бары тик Аллаһка карата гына буйсынучанлык тоя алу өчен, беренче чиратта, түбәндәгеләргә ирешү, төшенү кирәк;

– Бөтен көч-кодрәткә бары тик Аллаһ ия;

– Аның рөхсәтеннән башка һичбер мәхлук файда яки зарар китерергә сәләтле түгел;

– Һәрнәрсә фани, бары Ул гына бакый, мәңгелек;

– Һәрнәрсә Аңа мохтаҗ, Ул исә һичнәрсәгә мохтаҗ түгел;

– Аның һич тиңдәше юклыгына чын күңелдән ышану һәм бу ышануны ихлас иман югарылыгына күтәрү.

Шунлыктан, бәндәнең үз-үзен Аллаһка багышлавы Аллаһ турындагы белеме һәм Аңа карата иманына нисбәтле. Аллаһка буйсыну – гыйбадәтнең асылын формалаштыру ягыннан йөрәкнең Хак Тәгаләгә таба иң мөһим хәрәкәте. Бу хәрәкәт иман белән башлана, мәгърифәтуллаһ (Аллаһны танып белү) артканча, ул да көчәя һәм дәвам итә.

Үз-үзен Хак Тәгаләгә багышлауның иң күркәм үрнәкләреннән берсен Хәзрәти Ибраһим галәйһиссәләм күрсәтә. Аның йөрәгендә Аллаһтан башка һичбер нәрсәгә урын булмый. Ләкин фәрештәләр: «Йә, Раббы! Ибраһимнең жаны, баласы һәм малы бар! Ул Сиңа ничек “Хәлил” (дус) була ала?!» – дигәннәр.

Аллаһ Тәгалә исә Аның һич риясыз, каршылыксыз буйсынучанлыгын фәрештәләргә өч урында күрсәтә. Бу сынаулар һәм аларның нәтиҗәләре кыяматкәчә өммәткә үрнәк булып торачак.

Ибраһим галәйһиссәләм утка ыргытылырга тиешле вакытта, аңа фәрештәләр ярдәмгә килә. Әмма ул: «Мин сезгә мохтаҗ түгел! Утка яндыру көчен кем бирә?» – ди һәм: «Аллаһ нинди күркәм саклаучы!» – дип Раббысына сыена. Аның мондый буйсынучанлыгына әҗер буларак, утка: «И, ут! Ибраһим өчен салкынлык һәм тынычлык бул!» – дигән әмер бирелә.

Ата белән угыл, үзләрен Аллаһка багышлап, берсе корбан чалырга, икенчесе корбан булырга барганда, аларның Раббылары белән бәйләнешен өзәргә маташкан шайтанны бергәләп ташлар ыргыта-ыргыта куалар. Шул рәвешле алар Аллаһка буйсынучанлыкларының иң югары ноктасына ирешкән чакта, илаһи рәхмәт белән җәннәттән бер сарык иңдерелә.

Җәбраил галәйһиссәләм өч тапкыр зикер әйткәч, Ибраһим галәйһиссәләм, малының үзе өчен әһәмиятсезлеген белдереп: «Алып кит боларны!» – ди.

Рувәйм рәхмәтуллаһи галәйһи тәсаувыф[87] сүзенә мондый аңлатма бирә: «Тәсаувыф нәфесне илаһи максатка багышлау…»

Гыйбадәт буйсынучанлык булып тора, чөнки Аллаһ бәндәнең Үзеннән башка һичкемгә буйсынуын тыя һәм аның теләк-омтылышлар тырнагыннан котылуын тели.

Аяти кәримәләрдә болай диелә:

وَقَضَى رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ

**«Раббың сезгә Үзеннән башкаларга табынмаска, ата-анага игелек әмер итте…»** («әл-Исра», 23).

أَفَرَأَيْتَ مَنِ اتَّخَذَ إِلَهَهُ هَوَاهُ وَأَضَلَّهُ اللَّهُ عَلَى عِلْمٍ وَخَتَمَ عَلَى سَمْعِهِ
وَقَلْبِهِ وَجَعَلَ عَلَى بَصَرِهِ غِشَاوَةً فَمَنْ يَهْدِيهِ مِنْ بَعْدِ اللَّهِ أَفَلَا تَذَكَّرُونَ

**«Начар теләген илаһлаштырган, Аллаһ исә аны гыйлем нигезендә адаштырган, колагына һәм йөрәгенә мөһер суккан, күзенә дә пәрдә**

87. Тәсаувыф – дин өйрәтмәләрен серле һәм үзләренә генә билгеле бер рәвештә аңлау; рухи яктан камилләшү һәм ихсан дәрәҗәсенә ирешү юлларын өйрәтә торган фән.

**ташлаган кешене күрдеңме? Аллаһтан соң аны кем һидәяткә ирештерер? Әллә яхшылап уйламыйсызмы?»** («әл-Җасия», 23).

Аллаһка буйсынучанлык – мәхәббәткә нигезләнгән итагать гамәле. Бу итагать һәм буйсынучанлык бәрәкәте сәбәпле Ибраһим галәйһиссәләмгә җаны, малы һәм балалары Аллаһ юлында бернинди комачау тудыра алмый. Аның тарафыннан башкарылган хаҗ гыйбадәте исә Раббыга тәвәккәл кылуның, Аңа буйсынучанлыкның кыямәткә кадәр сакланачак иң күркәм символына әйләнә. Чөнки Ибраһим галәйһиссәләмнең теле, йөрәгенә тәрҗемәче булып, һәрдаим:

أَسْلَمْتُ لِرَبِّ الْعَالَمِينَ

**«…Мин галәмнәрнең Раббысына буйсындым!»** – дип кабатлый («әл-Бәкара», 131).

Хәзрәти Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимәс-сәләмнәр буйсынучанлыгының һәм Аллаһка тәвәккәл кылуларының символы булган хаҗ – Хак Тәгаләгә мәхәббәт белән тулы коллык чагылышы; кешелек сыйфатларыннан арынып, буйсынучанлык һәм үзеңне Аңа багышлау хисләре белән илаһи ярлыкану мохитенә адым ясау ул. Хаҗ өске һәм аскы яктан берәр тукыма кисәге белән капланган, баш һәм аяклар ачык калган хәлдә, бәндәнең барлык дөнья омтылышларыннан арынып, шул рәвешле Раббысына ихлас күңелдән сыгынуын белдергән тулысынча буйсыну халәте була.

Ихрамда вакытта хәтта бер үлән дә йолкып, бер төк тә өзеп алынмый һәм һичбер җанвар ауланмый. Бу гыйбадәтне башкарганда «рафәс», «фиск» һәм «җидал»[88] тыела. Бары тик Яралтучыга мәхәббәт сәбәпле сөю, мәрхәмәт һәм нәзакәтлелек кенә саклана. Хаҗ гыйбадәте безгә гөнаһларның ярлыкануы бары тик Хак Тәгаләгә ялварып, Аңа буйсынып һәм тәвәккәл кылып башкарылган гыйбадәт аркылы гына чынга ашуын раслый.

Раббыбыз безгә үз-үзебезне Аллаһка ихлас багышлап, Аңа гына тәвәккәл кылып яшәргә насыйп итсен! Бердәнбер яклаучыбыз һәм саклаучыбыз бары тик Бөек илаһи Зат булсын! Хисле күңел белән хаҗ кылу мөмкинлеген барыбызга да насыйп әйләсен!

Амин!..

88. Карагыз: «Бәкара» сүрәсе, 197 нче аять. Рафәс «җенси мөнәсәбәттән тыелу, бу хакта сөйләшмәү» һәм хәтта «һичбер төрле әшәке сүз әйтмәү» кебек мәгънәләр белдерә. Фиск – барлык гөнаһ-гамәлләр. Җидал –кирәксез бәхәсләр һәм тарткалашулар.

***Хәзрәти Исхак галәйһиссәләм***





# ХӘЗРӘТИ Лут *галәйһиссәләм*

### *Азгынлык һәм әхлаксызлыкта һәртөрле кабахәтлеккә әзер Содом халкын һидәяткә өндәгән*

# ХӘЗРӘТИ ЛУТ

### *галәйһиссәләм*

Лут галәйһиссәләм Ибраһим галәйһиссәләмнең туганы Харанның улы була. Исеме Коръәни-Кәримдә егерме җиде тапкыр искә алына.

Хәзрәти Лут галәйһиссәләм Ибраһим галәйһиссәләмгә беренче булып иман китерә, Аллаһ юлында аның белән бергә һиҗрәт кылу мәртәбәсенә ирешә. Хәзрәти Ибраһим юлындагы, аның шәригатендәге гыйбадәт әһеле, юмарт, сабыр, тәкъва, кунакчыл зат була. Тормышын терлекчелек һәм кул көче белән тәэмин итә.

Аллаһ Тәгалә болай ди:

وَلُوطًا آتَيْنَاهُ حُكْمًا وَعِلْمًا وَنَجَّيْنَاهُ مِنَ الْقَرْيَةِ الَّتِي كَانَتْ تَعْمَلُ الْخَبَائِثَ
إِنَّهُمْ كَانُوا قَوْمَ سَوْءٍ فَاسِقِينَ. وَأَدْخَلْنَاهُ فِي رَحْمَتِنَا إِنَّهُ مِنَ الصَّالِحِينَ

**«Лутка да Без хөкем (хакимлек, пәйгамбәрлек, хөкемдарлык) һәм гыйлем бирдек. Без аны кабахәт эшләр кылган авылдан коткардык. Һичшиксез, алар (ул авыл халкы) яман бер кавем, бозык кешеләр иде. Без аны (Лутны) рәхмәтебезгә керттек. Һичшиксез, ул изге кешеләрдән иде»** («әл-Әнбия», 74–75).

وَإِسْمعِيلَ وَالْيَسَعَ وَيُونُسَ وَلُوطًا وَكُلًّا فضَّلْنَا عَلَى الْعَالَمِينَ

**«Исмәгыйльне, Әльясагны, Юнысны һәм Лутны да (һидәяткә ирештердек). Барысын да галәмнәрдән өстен иттек»** («әл-Әнгам», 86).

Лут галәйһиссәләм пәйгамбәрлек вазифасын башкаруга Содомда керешә. Ул бу кала халкын Җәнабел-Хакка гыйбадәт кылырга чакыра.

#### Содом халкы

Содомлылар бик азгын һәм әхлаксыз кавем була. Бу халык үткәндәге милләтләрдә күрелмәгән һәртөрле бозыклыкны кыла. Җирәнгеч һәм пычрак бозыклыкларны оятсызларча эшләү генә түгел, хәтта тагын да уздырып җибәреп, бер һөнәр дәрәҗәсенә җиткерә. Аларны тыярга, комачауларга теләгәннәрнең исә: «Пакь затлар арабыздан чыксын!» – дип авызларын ябалар.

Бу кавемдә гыйффәт, оят һәм намус төшенчәләре онытылган була, алар хәтта хайваннар арасында да очрамаган әшәкелекләр, түбәнлекләр кылалар һәм Коръәни-Кәримдә әйтелгән «бәл һүм әдалл» (хайваннардан түбәнрәк) дәрәҗәсенә төшә.

Лут галәйһиссәләмгә әнә шундый кабахәт кавемне һидәяткә чакыру вазифасы йөкләнә. Ул аларны гафиллектән уяту өчен көн-төн тырыша. Аяти кәримәләрдә аның бу тырышлыгы болай дип телгә алына:

إِذْ قَالَ لَهُمْ أَخُوهُمْ لُوطٌ أَلَا تَتَّقُونَ. إِنِّي لَكُمْ رَسُولٌ أَمِينٌ. فَاتَّقُوا اللَّهَ وَأَطِيعُونِ. وَمَا أَسْأَلُكُمْ عَلَيْهِ مِنْ أَجْرٍ إِنْ أَجْرِيَ إِلَّا عَلَى رَبِّ الْعَالَمِينَ. أَتَأْتُونَ الذُّكْرَانَ مِنَ الْعَالَمِينَ. وَتَذَرُونَ مَا خَلَقَ لَكُمْ رَبُّكُمْ مِنْ أَزْوَاجِكُم بَلْ أَنْتُمْ قَوْمٌ عَادُونَ

**«Кардәшләре Лут аларга әйтте: “(Аллаһка каршы килүдән) Һич курыкмыйсызмы? Һичшиксез, мин – сезгә ышанычлы бер илчемен. Аллаһтан куркыгыз һәм миңа итагать итегез. Мин бит сездән моның өчен түләү сорамыйм. Минем әҗерем – Аллаһта гына. Галәмнәр арасыннан ирләргә киләсезме әллә? Һәм Раббыгызның сезнең өчен бар иткән хатыннарыгызны калдырасызмы? Юк! Сез чикне ашкан (адашкан) кешеләрсез!”»** («әш-Шугара», 161–166).

Содом халкы Лут галәйһиссәләмне гел алдый килә, аның дәгъватына колак салмый. Шуннан соң Лут галәйһиссәләм аларга бу бозыклыкларының куркынычы турында белдерә:

قَالَ لِقَوْمِهِ أَتَأْتُونَ الْفَاحِشَةَ مَا سَبَقَكُم بِهَا مِنْ أَحَدٍ مِنَ الْعَالَمِينَ

**«...Менә ул кавеменә әйтте: “Галәмнәрдән һичбере сезгә кадәр кылмаган шул кабахәт эшне кыласызмы әллә?”»** («әл-Әгъраф», 80).

Пәйгамбәр аларга кылган әшәкелекләренең һәлакәткә, казага илтәчәген хәбәр итә. Содомлылар исә Лут галәйһиссәләмне илләреннән куарга карар кыла:

وَمَا كَانَ جَوَابَ قَوْمِهِ إِلَّا أَنْ قَالُوا أَخْرِجُوهُمْ مِنْ قَرْيَتِكُمْ إِنَّهُمْ أُنَاسٌ يَتَطَهَّرُونَ

**«Кавеменең җавабы исә: “Аларны (Лутны һәм аның тарафдарларын) өлкәгездән куыгыз. Һичшиксез, алар – пакь булырга тырышкан кешеләр”, – дию генә булды»** («әл-Әгъраф», 82).

Саф тормыш, намуслы һәм гыйффәтле булу мондый азгын һәм әхлаксыз кавемдә гаеп санала. Үзләренең рухи азыклары нәҗес, бозыклык булганга күрә, пакь бәндәләр аларга ошамый, аларның эчләрен пошыра:

قَالُوا لَئِنْ لَمْ تَنْتَهِ يَا لُوطُ لَتَكُونَنَّ مِنَ الْمُخْرَجِينَ

**«И Лут! Әгәр дә (бу дәгъваттан) ваз кичмәсәң, (куып) чыгарылганнардан булачаксың!»** – дип яный алар («әш-Шугара», 167).

Хәзрәти Лут содомлыларга Аллаһның газабы турында искә төшерә:

وَلَقَدْ أَنْذَرَهُم بَطْشَتَنَا فَتَمَارَوْا بِالنُّذُرِ

**«Ул (Лут) аларны Безнең каты тотуыбыз (газабыбыз) белән кисәткән иде, ләкин алар аның куркыту-кисәтүләрендә шикләнделәр»** («әл-Камәр», 36).

Үз башларына төшәчәк фәлакәтнең дәһшәтен күзаллый алмаганлыктан, содомлылар илаһи кисәтүгә әһәмият бирми. Кимсетеп һәм бик батыраеп, алар Лут галәйһиссәләмгә:

ائْتِنَا بِعَذَابِ اللَّهِ إِنْ كُنْتَ مِنَ الصَّادِقِينَ

**«…Безгә Аллаһның газабын китер. Әгәр туры кешеләрдән булсаң!»** – дип җавап бирә («әл-Ганкәбут», 29). Содом халкы адашуын танырга, азгынлыктан баш тартырга җыенмый.

**Куркыныч тавыш һәм киптерелгән ташлар яву**

Лут галәйһиссәләм бик авыр шартларда (бер риваятькә күрә, 40 ел) көрәш алып бара. Ләкин кавеме кылган золым һәм бозыклыклары түзеп тора алмаслык дәрәҗәгә җитә. Содом халкы хәтта илаһи газап янавына да әһәмият бирмичә, өстәвенә, аны үзләре сорап алып, лаеклы рәвештә бик куркыныч газапка дучар ителә. Лут галәйһиссәләм мондый гаугалы, чуалчык вазгыятьтә Раббысына сыена һәм Аннан ярдәм сорый. Ул Аллаһ Тәгаләгә болай ялвара:

رَبِّ نَجِّنِي وَأَهْلِي مِمَّا يَعْمَلُونَ

**«И, Раббым! Болар кылган нәрсәләрдән мине һәм гаиләмне коткар!»** («әш-Шугара», 169).

قَالَ رَبِّ انصُرْنِي عَلَى الْقَوْمِ الْمُفْسِدِينَ

**«”И, Раббым! Бозык кавемгә каршы миңа ярдәм ит!” – диде»** («әл-Ганкәбут», 30).

Лут галәйһиссәләм, кавемен бәхеткә һәм һидәяткә ирештерү өчен, күп еллар тырышлык куя, әмма аңа ике кызы белән бергә бик азлар гына иман китерә. Хәтта хатыны да азгын кавемне яклый. Димәк, бу дога Лут галәйһиссәләм өчен соңгы чара була. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Лут кавемен һәлак итәр

өчен фәрештәләр җибәрә. Яшь егетләр кыяфәтендә килгән бу фәрештәләр азгын кавемдә гомосексуализм аркасында килеп чыккан дәрт-теләкләр уята. Һәм содомлылар аларга бозык тәкъдим белән сүз катарга маташа. Бу вакыйга Коръәни-Кәримдә болай тасвирлана:

وَلَمَّا جَاءَتْ رُسُلُنَا لُوطًا سِيءَ بِهِمْ وَضَاقَ بِهِمْ ذَرْعًا وَقَالَ هَذَا يَوْمٌ عَصِيبٌ

**«Илчеләребез Лутка килгәч, ул (Лут) алар өчен (азгын кавеменең аларны уңайсызлавы өчен) борчуга төште һәм көчсезлеге аркасында кыенлык кичерде дә: “Бу – бик читен бер көн”, – диде»** («Һуд», 77).

Фәрештәләрнең яшь егетләр кыяфәтендә килүен күргән Лут галәйһиссәләм аларны кеше дип уйлый һәм кавеме аларның намусына кул салыр дип курка, чөнки «Әгъраф» сүрәсенең 80–81 нче аятьләрендә белдерелгәнчә, Лутның Аллаһны инкяр иткән кавемендә җенси бозыклык киң таралган була.

وَجَاءَهُ قَوْمُهُ يُهْرَعُونَ إِلَيْهِ وَمِنْ قَبْلُ كَانُوا يَعْمَلُونَ السَّيِّئَاتِ قَالَ يَا قَوْمِ هَؤُلَاءِ بَنَاتِي
هُنَّ أَطْهَرُ لَكُمْ فَاتَّقُوا اللَّهَ وَلَا تُخْزُونِ فِي ضَيْفِي أَلَيْسَ مِنْكُمْ رَجُلٌ رَشِيدٌ

**«(Лутның) кавеме йөгерешеп аңа килде. Алар элек тә инде яман нәрсәләр белән мәшгуль иделәр. (Лут) әйтте:”И, кавемем! Менә минем кызларым (аларга өйләнегез), алар сезнең өчен тагын да пакь. Аллаһтан куркыгыз да, мосафирларым каршында мине хур итмәгез. Арагызда дөрес фикерле бер генә кеше дә юкмыни?”»** («Һуд», 78).

Кайбер тәфсир белгечләре фикеренчә, Хәзрәти Лутның кызларны хатынлыкка тәкъдим итүендә асыл максат үз кызларын кияүгә бирү түгел (чөнки аның ике генә кызы була), ә кавемендәге кызларны хатынлыкка алырга чакырудан гыйбарәт. Һәр пәйгамбәр үз кавеменең өлкән кешесе һәм рухи атасы саналганга, Хәзрәти Лут: «Менә болар минем кызларым», – дип әйткән. Әмма күзләре тонган содомлылар тәкъдимне кире кага:

قَالُوا لَقَدْ عَلِمْتَ مَا لَنَا فِي بَنَاتِكَ مِنْ حَقٍّ وَإِنَّكَ لَتَعْلَمُ مَا نُرِيدُ.
قَالَ لَوْ أَنَّ لِي بِكُمْ قُوَّةً أَوْ آوِي إِلَى رُكْنٍ شَدِيدٍ.

**«Алар әйттеләр: “Син безнең өчен кызларыңа бернинди хаҗәтебез булмаганны беләсең бит. Син безнең ни теләгәнебезне дә беләсең”. (Лут) әйтте: “Минем сезгә каршы (торырлык) көчем булса иде яки мин көчле бер таянычка сыена алсам иде!”»** («Һуд», 79–80).

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм, Хәзрәти Лутның үз кавеменә каршы әйткән бу сүзләрен искә алгач, мондый аңлатма бирә:

*«Лутка Аллаһының рәхмәте булсын. Ул бик нык нәрсәгә (Раббысына) сыена иде… Аллаһ Лутның әлеге догасы бәрәкәтендә аннан соң килгән бөтен пәйгамбәрләргә аларга таяныч булырлык нәсел-нәсәп һәм туганнар насыйп кыла»* (Ибне Хиббан, XIV, 86).

قَالُوا يَا لُوطُ إِنَّا رُسُلُ رَبِّكَ لَنْ يَصِلُوا إِلَيْكَ فَأَسْرِ بِأَهْلِكَ بِقِطْعٍ مِنَ اللَّيْلِ وَلَا يَلْتَفِتْ مِنْكُمْ أَحَدٌ إِلَّا امْرَأَتَكَ إِنَّهُ مُصِيبُهَا مَا أَصَابَهُمْ إِنَّ مَوْعِدَهُمُ الصُّبْحُ أَلَيْسَ الصُّبْحُ بِقَرِيبٍ

**«(Фәрештәләр) әйттеләр: “И, Лут! Без – Раббыңның илчеләребез. Алар беркайчан да сиңа ирешә (кагыла) алмаячаклар. Син төннең бер өлешеннән соң гаиләң белән бергә юлга чык. Әмма (хатыныңнан башка) сездән берегез дә борылмасын. Тик аларга киләчәк нәрсә хатыныңа да киләчәк. Һичшиксез, аларга вәгъдә ителгән вакыт (һәлакәт вакыты) – таң вакыты. Таң вакыты бик якын түгелме?”»** («Һуд», 81).

Бозык халык төркеме соңгы тапкыр Лут галәйһиссәләмнең ишеген ватарга талпынган мизгелдә барысының да күзләре сукырая. Аяти кәримәдә әлеге хикмәт хакында:

وَلَقَدْ رَاوَدُوهُ عَن ضَيْفِهِ فَطَمَسْنَا أَعْيُنَهُمْ فَذُوقُوا عَذَابِي وَنُذُرِ

**«Алар аның кунакларын аңардан (Луттан) таләп иттеләр, Без исә аларның күзләрен сукырайттык. “Минем газабымны һәм кисәтүләремне (әһәмият бирмәү җәзасын) татыгыз!” (дидек)»** – дип хәбәр ителә («әл-Камәр», 37).

Кади Бәйдави һәм Фәхреддин Разый аңлатмаларына ярашлы рәвештә, фәрештәләрнең берсе Җәбраил галәйһиссәләм була. Төркем ишекне ватып эчкә кергәч, ул бер селтәнүдә барысының да күзен сукырайта. Паникага бирелеп, качар өчен ишекне таба алмыйлар. Хәтта Лут галәйһиссәләм аларны кулларыннан тотып, тышка алып чыга.

فَلَمَّا جَاءَ أَمْرُنَا جَعَلْنَا عَالِيَهَا سَافِلَهَا وَأَمْطَرْنَا عَلَيْهَا حِجَارَةً مِنْ سِجِّيلٍ مَنْضُودٍ. مُسَوَّمَةً عِنْدَ رَبِّكَ وَمَا هِيَ مِنَ الظَّالِمِينَ بِبَعِيدٍ

**«Безнең әмеребез килгәч, өстен аска әйләндердек һәм аларга бер-бер артлы (пешерелеп) каткан балчыктан ташлар яудырдык. (Ул ташлар) Раббың хозурында тамгаланган (рәвештә яудырылды). Алар – залимнәрдән ерак түгел»** («Һуд», 82–83).

Лут кавеменә илаһи газапның килүе һәм һәлак ителүе «Хиҗер» сүрәсенең 58–77 нче аяти кәримәләрендә башка бер стильдә бәян кылына.

Коръәни-Кәримдә бу кавем яшәгән кала «асты-өскә китерелгән» дигән мәгънәдәге «әл-Мүэтәфикә» дип искә алына.

Лут кавеме гомосексуализм кебек җирәнгеч гөнаһлар кылганга күрә, Аллаһ Тәгалә аларга әүвәл куркыныч тавыш ишеттерә, аннары калаларын пыран-заран китерә, соңыннан өсләренә таш яудыра. Бер халыкның юкка чыгарылып, тарих сәхнәсеннән сөртелеп ташлануына моннан да куркынычрак фәлакәт була алмас!

Җәнабел-Хак бу кавем тарихында соңыннан яшәячәк кешеләр өчен бер гыйбрәт салынганлыгын хәбәр итә:

إِنَّ فِي ذَلِكَ لآيَاتٍ لِّلْمُتَوَسِّمِينَ وَإِنَّهَا لَبِسَبِيلٍ مُّقِيمٍ إِنَّ فِي ذَلِكَ لآيَةً لِّلْمُؤْمِنِينَ

**«Һичшиксез, күрә белгән күз белән караучыларга (гыйбрәт алучылар өчен) боларда билгеләр бар. Һичшиксез, ул урын – күз каршындагы бер юлда. Һичшиксез, мөэминнәр өчен боларда аять (гыйбрәт) бар»** («әл-Хиҗер», 75–77).

«Ганкәбут» сүрәсенең 35 нче аяти кәримәсендә дә, әлеге бозык кавемнең һәлакәте белән бәйле рәвештә, алардан соң киләчәк өммәтләргә гыйбрәт алыр өчен бик күп галәмәтләр күрсәтелгәнен белдерә:

وَلَقَد تَّرَكْنَا مِنْهَا آيَةً بَيِّنَةً لِقَوْمٍ يَعْقِلُونَ

**«Без акылларын кулланган кешеләр өчен аңардан ап-ачык бер аять (гыйбрәт) калдырдык».**

Мондагы «аять» сүзе һәлак ителгән кавем кичергәннәр белән бәйле вакыйгалар, җимерелгән йортларының калдыклары, күктән яудырылган ташлар һәм кап-кара булып аккан елгалар рәвешендә тәфсир кылына.

Фәхреддин Разый Лут кавеме турында сөйләгән аяти кәримәләрнең Мәккә мөшрикләренә атап иңдерелгәнен искә ала да, «Һичшиксез, ул урын күз каршындагы бер юлда» аяти кәримәсенә таянып: «Мәккәлеләр сәүдә өчен күпчелек Димәшкъ шәһәренә баралар. Димәшкъ юлы Лут күленең (Үле диңгезнең) нәкъ көньягыннан уза торган була. Шунлыктан Лут кавеменең калдыкларын шуннан эзләргә кирәк», – дип аңлата.

### Лут галәйһиссәләмнең хатыннары һәм балалары

Пәйгамбәрлек вазифасы йөкләнгән чакта Лут галәйһиссәләмнең иманга килгән Фәват исемле хатыны була. Бу хатын егерме елдан соң бакыйлыкка күчә. Аның вафатыннан соң, Лут галәйһиссәләм Вахилә исемле Содом хатынына өйләнә. Ләкин Вахилә монафикъ хатын була. Кавемнең имансызлыгына

һәм бозыклыгына карата берни дә дәшми. Хәтта Лут галәйһиссәләмгә каршы көрәштә яшерен рәвештә кавеменә булышлык та күрсәтә.

Бер кичне азгын кавемне һәлак итү вазифасы йөкләнгән фәрештәләр, чибәр йөз-битле кешеләр кыяфәтендә, Лутның йортына килгәч, Вахилә шундук чыгып китә дә, бу хакта кавеменә хәбәр салып, иренә хыянәт кыла. Шул рәвешле ул да кавеме белән бергә һәлак ителә.

Лут галәйһиссәләмнең ике иманлы кызы була. Лут кавеме һәлак ителгән чакта, алар әтиләре һәм иманга килүчеләр белән бергә Содомнан чыгып китә һәм илаһи газаптан котыла. Аннары алар, аталары белән бергәләп, Ибраһим галәйһиссәләм янына юл тота. Ибраһим галәйһиссәләм бу ике кызны үз кавеменнән ике мөэмин ир-егет белән кавыштыра. Бөек Аллаһ Лут нәселенә бәрәкәт индерә. Мәдьян халкы алардан барлыкка килә.

**Лут кавемендәге яман гамәлләр һәм һәлак ителү сәбәпләре**

1. Потларга табыну.

2. Гомосексуаль мөнәсәбәтләр (ливата, ир-атның ир-ат белән якынлык кылуы).

Ибне Габбастан риваять кылынган хәдис-шәрифтә:

«*Лут кавеменең әшәке эшен күрсәгез, фәгыйлен дә (башкаручыны – субъектны да), мәфгулен дә (бу гамәл объектын да) үтерегез!*» – дип әйтелә (Тирмизи, «Худуд», 24/1456; Әбү Давыт, «Худуд», 28/4462).

Ибне Габбастан тапшырылган башка бер риваятькә күрә, Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

«*Лут кавеме гамәлен (ливата) кылучы – мәлгунь (ләгънәтләнгән)*», – дип өч тапкыр кабатлый (Тирмизи, «Худуд», 24/1456; Әхмәд, I, 317).

Малик ибне Динар болай дип яза:

«Үткәндәге өммәтләрнең һичкайсында ливата турында сүзләр ишетелми. Ләкин бу әшәке гамәл Лут кавеме арасында тарала. Аларга исә бу әшәкелекне шайтан өйрәтә. Һәм кешеләр, яратылышларына каршы килгән бу гамәлне эшләгәч, илаһи газапка тарыйлар һәм ахирәт җәзасына дучар ителәләр.

Аллаһ Тәгалә кешегә шәһвәтне нәселен күбәйтү өчен биргән. Аны, бирелү максатына һәм хикмәтенә ярашсыз юлда кулланып, сукырларча гамәл кылу бәндәнең җаһиллеге һәм азгынлыгы аркасында килеп чыга. Бу исә кешелек абруен һәм намусын аяк астына салып таптап, хайваннардан да түбән дәрәҗәгә төшү дигән сүз».

3. Ливата белән үтерү.

Лут кавеменең азгын бәндәләре, берәрсен үтерергә теләгәндә, ул кешегә ливата кылырга (җенси көчләргә) карар кылып, шул рәвешле газаплаганнан соң гына үтерә торган булганнар.

4. Содомлылар гыйффәтсезлекләрен яшермиләр, оятсыз эшләрен ачыктан-ачык башкаралар. Гыйффәтле бәндәләрне гаеплиләр. Шулкадәр түбәнлеккә төшәләр ки, хәтта артта җил чыгаруны да ачыктан-ачык күңел ачу чарасына әйләндерәләр.

Лут кавеме яман эшләрдә шулкадәр арттырып җибәрәләр ки, гыйффәтле яшәп, үзләрен нәсыйхәтләгән затларны бөтенләй яратмыйлар. Лут галәйһиссәләмгә: «И Лут! Әгәр дә (бу сүзләрдән, бу дәгъваттан) ваз кичмәсәң, (куып) чыгарылганнардан булачаксың!» – диләр.

5. Юлбасарлык. Юлдан узып баручыларга таш ату.

Үзләре янына чуерташлар җыеп, алар юлга чыгып утыралар. Чит кеше үткәндә, аның өстенә таш ыргытып, кимсетәләр.

6. Гайбәт, имеш-мимеш тарату (сүз йөртү).

7. Саранлык.

Хәсән Басридән тапшырылган бер риваятькә күрә, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Лут кавеменең һәлак ителү сәбәпләрен санагач, хәдиснең дәвамында болай дип әйтә:

*«Өммәтем бу әхлаксызлыкларга тагын хатын-кыз белән хатын-кызның якынлык кылуын да (лесбианлык) өстәр...»* (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 51, № 8150).

Аллаһ Тәгалә Лут кавеменең һәлакәтеннән гыйбрәт алырга куша һәм юк ителгән кавемнең калдыкларын кешелек тарихы өчен бер сабак итеп калдырылганын белдерә. Лут күленә (Үле диңгезгә) салынган «ап-ачык аятьләр» чыннан да бик кызыклы. Үле диңгез тирәсендә булган вакыйгалар кебек, бу территориянең геологик хәле дә игътибарга лаек. Күл Ак диңгез өслегеннән дүрт йөз метр түбәнрәк урнашкан. Лут күленең иң тирән урыны дүрт йөз метр тәшкил итә. Лут күле тирәсеннән кала, дөньяның диңгез өсте тигезлегеннән иң түбән урыны бары йөз генә метр астарак урнашкан. Гүя бу территориянең төзелеше дә Лут кавеменең түбәнлеген раслый.

«Рум» сүрәсенең 3 нче аяти кәримәсендә дә, бу төбәккә ишарәләп, **«әднәлард – җир йөзенең иң түбән урыны»** гыйбарәсе кулланыла. Бу сүзтезмә, гарәпләр яшәгән өлкәгә якынлыгына нигезләнеп, «иң якын урын» дип аңлатылса да, сүзләрнең төп мәгънәсе «җир йөзенең иң түбән урыны» дигәнне белдерә. Хәзерге заманның алдынгы техник чаралары ярдәмендә Җир шарының иң түбән урыны тикшерелгәч, бу урынның аяти кәримәдә искә алынган Лут күле бассейны икәнлеге ачыклана. Коръән иңдерелгән чорда мондый гео-

логик хакыйкать кешеләр тарафыннан билгеләнә алмаганга күрә, бу хикмәт Коръәни-Кәримнең Аллаһ кәламе булганлыгына соңгы вакытларда ачылган тагын бер фәнни дәлил булып тора.

Үле диңгезнең тагын бер үзенчәлеге – тозлылык дәрәҗәсенең 30% тәшкил итүеннән гыйбарәт. Шунлыктан күлдә балыклар да яшәми, үсемлекләр дә үсми. Әнә шуңа күрә дә бу күлне Үле диңгез – «бахрүл-мәййит» дип атыйлар да. Әлеге ләгънәт төшкән урында хәтта хайваннар да яшәмәве үзе бер гыйбрәт булып тора. Кап-кара диярлек төстәге күл җирәнгеч, сасы исләр бүлеп чыгара, әйтерсең, ул сулык бу тирәдә эшләнгән гөнаһларны әнә шул шыксыз манзарасы аша кешелеккә ачып бирә.

Коръәни-Кәримдә бәян ителгән бу мәлгунь кавем белән бәйле вакыйгалар, фаразлар буенча, безнең эрага кадәр 1800 нче елларда була. Һәлакәткә тарыган Содом һәм Гоморра тирәләрендә шул чордан калган тоз концентрациясе аркасында консервлангандай сакланган агачлар табыла. Шәһәр хәрабәләре исә илаһи газап тәэсирендә җир астына чума.

Содом-Гоморра шәһәрләренең башларына төшкән илаһи ачу белән «Помпей фаҗигасе» бер-берсенә бик охшаган.

**Помпей халкының һәлак ителүе**

Помпей Рим императорлыгының деградация символына әйләнгән Италиядә урнашкан була. Помпей шәһәре дә нәкъ Лут кавеме кебек җенси бозыклык сазлыгына бата. Тарихи елъязмалар, юк ителер алдыннан, шәһәрдәге хәлләрне бозыклык, әдәпсезлек, чиктән ашкан әхлаксызлык дип бәяли. Гайсә галәйһиссәләмнән җитмеш ел соңрак Везувий вулканының көтмәгәндә шартлап атуы аркасында чыккан лава мизгел эчендә каланы җир йөзеннән сөртеп ташлый, илаһи газаптан һичкем качып котыла алмый. Кабахәт ахмаклар ачыктан-ачык бозыклыкка чумган хәлдә, таштай катып калалар.

Бу вакыйга күз ачып йомган арада килеп чыга. Барлык әхлаксызлар әлеге илаһи җәзага бер мизгел эчендә тартыла. Аларның калдыклары, һич бозылмыйча-таркалмыйча, хәзерге көнгә кадәр бик зур гыйбрәт бирә.

Коръәни-Кәримдә моңа охшаш, көтмәгәндә һәлак ителү вакыйгалары турында болай диелә:

إِنْ كَانَتْ إِلَّا صَيْحَةً وَاحِدَةً فَإِذَا هُمْ خَامِدُونَ

**«(Аларга) фәкать бер көчле тавыш кына булды һәм алар шундук сүнделәр»** («Йәсин», 29).

Помпей халкы да шул рәвешле, көтмәгәндә һәлак ителә. Якынча мең тугыз йөз ел әүвәлгерәк вакыттан бүгенгә кадәр ташка әйләнеп сакланган

кабахәт бәндәләрнең ямьсез, куркыныч манзаралары тарихның гыйбрәтле бер сәхифәсен тәшкил итә.

Аллаһ Тәгалә болай ди:

وَكَمْ أَهْلَكْنَا قَبْلَهُمْ مِنْ قَرْنٍ هَلْ تُحِسُّ مِنْهُمْ مِنْ أَحَدٍ أَوْ تَسْمَعُ لَهُمْ رِكْزًا

**«Без алардан әүвәл ничәмә-ничә буыннарны һәлак иткән идек! Син алардан берәрсен таба аласыңмы? Яки аларның пышылдавын булса да ишетә аласыңмы?»** («Мәрьям», 98).

Тарихның гыйбрәт белән тулы сәхифәләрен халыклар каберлеге дип атарга мөмкин. Имансызлык, әхлаксызлык һәм золым – халыкларның иң төп һәлакәт һәм юк ителү сәбәпләре ул. Имансыз һәм залим кавемнәрнең үлем алды агониясе илаһи нәфрәтнең нинди куркыныч чагылышы булып тора. Инде күп гасырлар узуга карамастан, Помпей бүген, әйтерсең, әхлаксыз бәндәләрнең ташка әйләнгән гыйбрәтле мисалларын күрсәтә. Гүя хайванга әйләнгән кеше силуэтлары алар!..

Бу гыйбрәт күренешләре хакыйкатьне күрә алмаган, юк ителү турында бәяннарны нәфес коткысында тыңлап, асылына төшенмәгән аңсызлар, акылсызлар өчен дә җиңел аңларлык гади һәйкәллләрдән, үрнәкләрдән гыйбарәт.

Җир астына чумган азгын, гыйффәтсез һәм оятсыз кабахәтләрнең оясы – Содом белән Гоморраны да, дөньяны үзләренә һәрвакытка бүләк ителгән бәхет тәхете, дип уйлаган, нәфесләрен потка әйләндергән Гад белән Сәмудның да ташлардан уеп ясалган искиткеч сарайларын бүген бары ябалак-байгышлар гына җанландырып тора!..

# ӘХЛАК КҮРКӘМЛЕГЕ ҺӘМ НӘСЕЛНЕ САКЛАУ

Өстен сыйфатлар чиксез күркәмлек һәм нәфислек үрнәге итеп яралтылган кешенең асыл кыйммәте, Аллаһка гыйбадәт кылып һәм Раббының бөеклеген аңлап, үзенә тиешле илаһи серләргә ирешә алудан гыйбарәт.

Табигать һәм андагы мәхлукларның, искиткеч күренешләрнең һичшиксез билгеле бер максаты бар. Кеше дә сәбәпсез бер маҗара аркасында барлыкка килгән әсәр түгел. Ничек тели, шулай яшәсен, дип яралтылмаган бәндә. Аның бар ителүенә илаһи максат салынган. Раббының күркәм һәм матур сыйфатлары кешедә чагылыш табып, ул Раббысына «хәлил» (дус) була ала.

Башка мәхлуклар исә кешене яшәтү өчен бар ителгән. Ә кеше «хәлифә» итеп куелган. Хәлифәлек фидакяр кешеләргә насыйп ителгән вәкаләт булып тора. Җәнабел-Хакның бу вәкаләтен тиешенчә башкаручыларның күрергә сәләтле күзе, ишетә торган колагы булыр. Бу исә Коръәни-Кәрим әхлагын үзләштерү аша чынга аша ала. Мондый әдәп-әхлакның иң югары ноктасы турында Аллаһ Тәгалә болай ди:

وَلَا تَسْتَوِي الْحَسَنَةُ وَلَا السَّيِّئَةُ اِدْفَعْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ فَإِذَا الَّذِي بَيْنَكَ وَبَيْنَهُ عَدَاوَةٌ كَأَنَّهُ وَلِيٌّ حَمِيمٌ. وَمَا يُلَقَّيهَا إِلَّا الَّذِينَ صَبَرُوا وَمَا يُلَقَّيهَا إِلَّا ذُو حَظٍّ عَظِيمٍ

**«Яхшылык белән явызлык тиң түгел. Син иң яхшы мөгамәлә белән кайтар, шулвакыт сиңа дошман кеше гүяки шәфкатьле бер дус (булып куяр). Әмма бу сабыр иткән кешеләргә генә бирелер. Бу зур бер насыйп иясе булганнарга гына бирелер»** («Фуссыйләт», 34–35).

Коръән кешене әхлакның иң фазыйләтле ноктасына күтәрә, чөнки бөтен гыйбадәтләр һәм зикерләр күркәм әхлак белән камиллеккә ирешер. Әйтик, Хәсән Басри рәхмәтуллаһи галәйһи аның хакында сүз йөрткән, гайбәт сөйләгән кешегә начарлык белән җавап бирми, киресенчә, бүләк җибәреп, гөнаһларын үзенә алган өчен, рәхмәт әйтә торган була.

Илаһи күркәмлек җыелмасы рәвешендә дөньяга килгән кешегә, тормыш сынауларын кичкәндә, хәерлене яки яманны, гөнаһлыны сайлау мөмкинлеге тудырган ирек бирелә. Бәндә нәфесендә яшеренгән гөнаһ омтылышлары һәм йөрәгендәге тәкъвалык теләге белән күзгә-күз калдырыла.

Начар холык сыйфатларының яралтылуы тормыш имтиханында бәндәне сынау өчен кирәк. Коръәни-Кәримдә:

وَنَفْسٍ وَمَا سَوّٰيهَا. فَأَلْهَمَهَا فُجُورَهَا وَتَقْوٰيهَا. قَدْ اَفْلَحَ مَنْ زَكّٰيهَا. وَقَدْ خَابَ مَنْ دَسّٰيهَا

**«Җан һәм аны төзек кылучы белән (ант итәм). Һәм аның күңеленә бозыклыкны һәм тәкъвалыкны салучы (белән). Аны (нәфесен начарлыклардан) арындырган кеше уңышка ирешкән. Аны яшергән (гөнаһ һәм буйсынмаучанлык белән пычраткан) кеше зарар күргән»**, – дип әйтелә («әш-Шәмс», 7–10).

Димәк, кешене кеше иткән нәрсә – күркәм холык сыйфатлары; ә яман холык исә аны, киресенчә, кешелектән чыгара.

Аллаһ яралткан дөньяда, Аның нигъмәтләре эчендә яшәгән хәлдә, Аның кушканнарына һәм тыюларына каршы килү – дөм караңгылык һәм ахыры куркыныч ахмаклык булып тора. Иман һәм әхлак кагыйдәләренә буйсынмаганнар һәм залимнәр илаһи ачу-нәфрәткә дучар ителәчәк.

Кешечә яшәүнең бердәнбер юлы – дин һәм әхлак. Кешелекнең иң камил заты һәм иң мөкәммәл әхлак үрнәге исә – Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм ул.

Аяти кәримәдә:

لَقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللّٰهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِمَنْ كَانَ يَرْجُوا اللّٰهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللّٰهَ كَثِيرًا

**«Сезнең өчен Аллаһка һәм соңгы көнгә (ахирәт көненә) өмет баглаган һәм Аллаһны күп итеп искә алган кешеләр (мөэминнәр) өчен Аллаһның Рәсүлендә күркәм үрнәк бар»**, – дип хәбәр ителә («әл-Әхзәб», 21).

Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Мине Раббым тәрбияләде һәм бик күркәм тәрбияле итте»*, дип (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», I, 12), Мөхәммәд шәхесендәге югары әхлаклылыкны телгә ала. Шуңа күрә кешенең яратылыш сере Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хикмәтен тану аша чишелә ала. Аны никадәр яхшырак таный алсак, илаһи серләр-хикмәтләр дә шулкадәр тирәнрәк ачылыр.

Раббыбыз һәрбарчабызны Аллаһ Рәсүленең әхлак һәм бәхет байрагы астында тупласын!

Амин!..

**Нәселне саклау**

Нәсел, җенси гыйффәтлелек, намус һәм гаилә кору илаһи нигъмәт булган яшәешнең табигый нәтиҗәләре булып тора.

Адәм галәйһиссәләмнән бирле бөтен шәригатьләрнең пәйгамбәрләре, гаилә кору канунының ныклыгын, саулыгын тәэмин итү өчен, никах

мәсьәләсенә бик җитди караган, чөнки нәселне җәмгыятьтәге никах институтының ныклыгы бәрабәренә генә сакларга, булдырырга мөмкин. Гаилә эчендә тәрбия күрмәгән, никахсыз дөньяга килгән балалар тормышны бутыйлар, иҗтимагый иминлек-муллыкның нигезен җимерәләр, анархиягә китерәләр… Никах бәхетен фәхеш нәҗеслегенә алыштырудан зуррак тилелек һәм наданлык була да алмый!..

Ныклы, тәрбияле нәсел дәвамчылары үстерү – кешелекнең иң зур бәхете. Балалар тәрбияләү турында хәдис-шәрифтә:

*«Бер ата да баласына күркәм әхлактан хәерлерәк мирас калдырмаган»*, – дип әйтелә (Тирмизи, «Бирр», 33).

Балаларны үстергәндә күргән авырлыклар, борчу-мәшәкатьләр гөнаһларның ярлыкануына бер сәбәп булыр.

Аллаһ гыйбадәтханә итеп яралткан бу дөньяда, Аның каршында коллыкның чагылышын, рухи мәртәбәләрен, бәндәчел дәрәҗәсен һәм кыйммәтләрен югалткан илләрнең җиһан картасыннан ничек сөртеп ташланганлыкларын бар галәмгә гыйбрәт итеп бәян кылган Коръәни-Кәрим кешеләргә туры юлны күрсәтә торган утны тотып бара һәм мәңгелек бәхет юлларын яктырта.

Раббыбыз безгә биргән нигъмәтләрен үз ризалыгына ярашлы итеп куллануыбызны насыйп кылсын!..

***Хәзрәти Лут галәйһиссәләм***





ХӘЗРӘТИ

# Зөлкәрнәйн

*галәйһиссәләм*

## *Тәүхид байрагын Көнчыгыш һәм Көнбатышка күтәреп барган*

# ХӘЗРӘТИ ЗӨЛКӘРНӘЙН

### *галәйһис-сәләәм*

«Зөлкәрнәйн» сүзе «ике гасыр иясе» дигәнне белдерә. Дөньяның көнчыгышын һәм көнбатышын гизүе, Аллаһның аңа нур белән караңгылыкны буйсындыруы кебек сәбәпләргә нигезләнеп, Зөлкәрнәйн кушаматы бирелгәнлеге риваять кылына.

Хәзрәти Зөлкәрнәйннең пәйгамбәр булганмы әллә әүлиямы икәнлеге мәсьәләсендә бәхәс тынмый. Коръәни-Кәримдә аның Шәрыккә һәм Мәгърибкә сәфәр кылуы искә алына. Хәзрәти Зөлкәрнәйн Хәзрәти Нухның улы Яфәс нәселеннән килә. Чын исеме – Искәндәр. Ләкин Хәзрәти Зөлкәрнәйнне Александр Македонияле белән бутарга ярамый. Тарихта билгеле Бөек Александр безнең эрага кадәр III гасырда Македониядә туа, Һиндстанга кадәр сәфәр кыла. Аристотельнең шәкерте санала. Искәндәр Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм исә Хәзрәти Ибраһим галәйһис-сәләәм заманында яши. Хәтта аның белән хаҗ кыла, аның догасына лаек була.

Александр Македонияленең походлары, Хәзрәти Зөлкәрнәйннең сәфәрләре кебек, Шәрык белән Мәгърибтәге җиңүләр дип карала алмый. Александр Македонияле, тарихи мәгълүматларга күрә, бернинди дә дивар төземәгән. Шунысын да әйтергә мөмкин: Александр Македонияле Аллаһка иман китергән зат булмый. Үзе яулап алган халыкларга карата да шәфкатьле һәм гадел мөнәсәбәт күрсәтми. Бөтен тормышы тарих сәхифәләренә теркәлгән бу Искәндәр (Александр) Македонияле белән Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәмнең эш-гамәлләре арасында тырнак очы кадәр дә охшашлык юк. Өстәвенә, Александр Македонияленең «Зөлкәрнәйн» кебек мактаулы кушаматка ия булырдай һичбер үзенчәлеге дә билгеле булмый.

Риваятькә күрә, Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм әнисенең сеңлесенең улы Хозыр галәйһис-сәләәмгә үз гаскәрендә командир вазифасын йөкли. Кяферләргә каршы сугыша. Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ кавеменнән саклану өчен, бакыр һәм тимердән дивар-коймa ясый. Аллаһ динен, тәүхид гакыйдәсен тарату белән шөгыльләнә; кешеләрне хак белән хакыйкатькә өнди.

Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм Мәдинәи Мөнәввәрә белән Димәшкъ арасындагы «Дүмәтүл-Җәндәл» дип аталган җирдә вафат була. Мәккә тирәсендәге «Тиһамә» тауларына җир куенына иңдерелә.

Куртуби тәфсирендә риваять ителгәнчә, барлыгы дүрт кеше генә бөтен җир йөзендә хакимлек кыла алган. Аларның икесе – мөэмин, икесе – кяфер.

Зөлкәрнәйн белән Сөләйман галәйһимәс-сәләмнәр – мөэминнәр; кяферләре исә – Нәмруд белән Бухтүннаср. Бөтен дөньяга хаким булачак бишенче шәхес исә өммәтебездән чыгачак. **«Аллаһ исламны бөтен диннәрдән өстен кылачак»** аятенә («Тәүбә», 33) ярашлы рәвештә, сүз Мәһди галәйһис-сәләәм турында бара (Куртуби, «Тәфсир», XI, 47–48).

Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе, дөньяның көнчыгышына һәм көнбатышына барып җитәр өчен, Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәмнең ничек көче җитә алганлыгы турында сорауга болай дип җавап бирә: «Аңа болытлар буйсындырылыр, кирәкле һәрнәрсә аның кул астына бирелер, нурлар да аңа яктырта, төн белән көн дә аның өчен бертигез булыр» (Ибне Исхак, «Сыйрәт», 185 б.).

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәдә яшәгән борынгы кавемнәрнең башыннан кичкән вакыйгалар турында сөйләгәндә, яһүдиләр һәм фарсылар элекке өммәтләргә бәйле хикәятләрне үзләренчә бәян итә башлый. Мәдинәдә Ахырзаман Пәйгамбәренең үз араларыннан чыгачагына ышанган яһүдиләр була. Алар Мәккә мөшрикләренә: «Анда бер Пәйгамбәр барлыкка килгән, әгәр ул чын Пәйгамбәр икән, аннан Әсхабе Кәһф, Зөлкәрнәйн һәм җанның сыйфаты турында сорагыз! Әгәр Әсхабе Кәһф белән Зөлкәрнәйн турында тулы, җанның сыйфатлары турында өлешчә җавап бирсә, чыннан да Пәйгамбәр булыр, аңа иярегез! Ләкин ул шул өч нәрсә турында бернинди дә хәбәр бирә алмаса, ялганчыдыр!» – диләр.

Мәккәле мөшрикләр исә Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Әсхабе Кәһф һәм Шәрык белән Мәгърибкә сәфәр кылган Зөлкәрнәйн кемнәр ул? Җан нинди була?» – дип сорыйлар.

Шуннан соң «Кәһф» сүрәсе иңә. Бу сүрәдә Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм телгә алына:

وَيَسْـَٔلُونَكَ عَنْ ذِى الْقَرْنَيْنِ قُلْ سَاَتْلُوا عَلَيْكُمْ مِنْهُ ذِكْرًا ﴿٨٣﴾
اِنَّا مَكَّنَّا لَهُ فِى الْاَرْضِ وَاٰتَيْنَاهُ مِنْ كُلِّ شَىْءٍ سَبَبًا ﴿٨٤﴾

**«Синнән Зөлкарнәйн турында сорыйлар. Әйт: “Сезгә аның турында хәбәр бирермен”. Һичшиксез, Без аңа җирдә көч һәм мөмкинлекләр бирдек, һәм Без аңа (максатына ирешергә теләгән) һәр эштә сәбәбен бирдек»** («әл-Кәһф», 83–84) (Алуси, «Тәфсир», XVI, 24; Вахиди, 306 б.).

**Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәмнең мөһим сыйфатлары**

1. Аллаһ Тәгалә Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәмгә көч-куәт бирә. Һәм ул Көнчыгышка һәм Көнбатышка сәфәрләр кыла, аның үз исеме белән йөртелгән диварны кора. Бу дивар бакыр кушылган тимердән була.

2. Болытлар һәм башка чаралар Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәмгә буйсындырыла.

3. Аңа гыйлем һәм кодрәт бирелә. Шуларны кулланып, ул искиткеч хакимлеккә ирешә.

4. Аңа ак һәм кара байрак бирелә. Көндез каядыр барганда, кара байрагын аркасына куйгач, аның арткы тарафын караңгылык каплый. Шул рәвешле дошман аны таба алмыйча, юлдан яза һәм, караңгылыкта калып, җиңелүгә дучар ителә. Төнлә исә ак байрагын алдында тотып, үзенә һәм гаскәрләренә көндезге кебек яктылык тәэмин итә һәм дошманнары белән сугышта зур җиңүләр яулый.

5. Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм гадел, үз кул астындагыларга карата мәрхәмәтле хөкемдар була. Үзе яулап алган өлкәләрдәге кешеләргә: «Арагызда гаепсезләр өчен борчылыр нигез юк, игелек кылучылар моның әҗерен алыр», – дип, мәрхәмәтлелеге, толерантлыгы һәм хәлгә керә белүчәнлеге белән кешеләр күңелендә хөрмәт казана. Кешелек файдасына булган һәрнәрсәне ярата.

6. Ачкүзлелек, саранлык хисенә бирелмәгән бәндә була. Кешеләр дивар кору өчен аңа матди ярдәм тәкъдим иткәч: «Аллаһ миңа насыйп кылган нәрсәләр бәрабәренә мине сезгә мохтаҗлыктан азат кылды. Сез миңа шәхсән хезмәт куеп, кул көчегез белән булышыгыз», – дип әйтә.

7. Юмарт зат була. Башка хөкемдарлар кебек байлык артыннан кумый. Мул итеп сыйлый торган, хаталарны кичерүчән, кече күңелле һәм шәфкатьле хөкемдар булуы белән аерылып тора.

8. Тәкъвалык һәм хикмәт иясе, хөрмәтле зат була. Төп максаты кешелеккә хезмәт итү һәм золымга тарыган бәндәләргә карата гаделлек күрсәтүдән гыйбарәт. Аның фикеренчә, байлык хөкемдарларның муллыгы, иминлеге түгел, халыкка хезмәткә сарыф итәр өчен бирелә.

**Тәүхидкә өндәү өчен сәфәрләре**

Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм дәүләтенең көч-куәтен арттырып, чикләрен киңәйтә. Аллаһ кушканнарны һәм Аның тыйганнарын дөньяга өйрәтә, тарата башлый. Мөэминнәрдән оешкан армиясе белән ул иң элек көнбатышка юнәлә. Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм һәркайда кяферләрне тәүхид дингә чакыра. Ул көнбатышның иң чик ноктасына кадәр барып җитә. Коры җир бетә, киң диңгез ярына килеп чыга. Кояш, әйтерсең, кара балчыклы елгага бата кебек тоела. Анда бер кяфер кавемне очрата. Аларның бер өлеше иман китерә, Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм диннән баш тартканнарына каршы сугыш ачып, аларның барысын да җиңә. Ахырда алар да, тәүбә итеп, барысы бергә тәүхид гакыйдәсен кабул итә. Аяти кәримәдә бу хәл түбәндәгечә тасвирлана:

فَأَتْبَعَ سَبَبًا. حَتَّى إِذَا بَلَغَ مَغْرِبَ الشَّمْسِ وَجَدَهَا تَغْرُبُ فِي عَيْنٍ حَمِئَةٍ وَوَجَدَ عِنْدَهَا قَوْمًا قُلْنَا يَا ذَا الْقَرْنَيْنِ إِمَّا أَنْ تُعَذِّبَ وَإِمَّا أَنْ تَتَّخِذَ فِيهِمْ حُسْنًا.

**«Һәм ул (көнбатышка таба юнәлеп) бер сәбәпкә иярде. Ниһаять, кояш баеган җиргә ирешкәч, аның (гүя) кара балчыклы чишмәдә батканын күрде. Аның янында ул бер кавемгә тап булды. Без аңа: “И, Зөлкарнәйн, йә аларга газап бирәчәксең, йә аларга карата нindидер игелек кылачаксың”, – дидек»** («әл-Кәһф», 85–86).

Үзенә шундый сәләт бирелгән Хәзрәти Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм илаһи әмер кысаларында эш йөртә:

قَالَ أَمَّا مَنْ ظَلَمَ فَسَوْفَ نُعَذِّبُهُ ثُمَّ يُرَدُّ إِلَى رَبِّهِ فَيُعَذِّبُهُ عَذَابًا نُكْرًا. وَأَمَّا مَنْ آمَنَ وَعَمِلَ صَالِحًا فَلَهُ جَزَاءً الْحُسْنَى وَسَنَقُولُ لَهُ مِنْ أَمْرِنَا يُسْرًا

**«(Ул) әйтте: “Кем дә кем хаксызлык кыла, аны җәзага дучар итәчәкбез, шуннан ул Раббысына кайтарылачак, шуннан Ул аңа куркыныч газап бирәчәк. Әмма кем дә кем иман итеп, изге гамәл кылса, аңа иң яхшы әҗер булыр. Һичшиксез, әмерләребездән аңа кулай булганын әйтербез”»** («әл-Кәһф», 87–88).

Әнә шул рәвешле Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм кешеләрне һәрдаим иманга чакыру белән шөгыльләнә. Аңа буйсынучылар котылуга ирешә, иман китермәгәннәр исә җәзасын татый.

Көнбатышка сәфәрдән соң Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм көнчыгышка юл тота һәм кояш чыккан җиргә китә. Аятьтә болай диелә:

ثُمَّ أَتْبَعَ سَبَبًا. حَتَّى إِذَا بَلَغَ مَطْلِعَ الشَّمْسِ وَجَدَهَا تَطْلُعُ عَلَى قَوْمٍ لَمْ نَجْعَلْ لَهُمْ مِنْ دُونِهَا سِتْرًا. كَذَلِكَ وَقَدْ أَحَطْنَا بِمَا لَدَيْهِ خُبْرًا

**«Шуннан соң ул янә бер сәбәпкә иярде. Ниһаять, кояш чыккан җиргә ирешкәч, аның шундый бер кавем өстенә чыкканын күрде, Без аларга аңардан (эсселектән) каплана торган берни дә бирмәгән идек. Шулай (Зөлкәрнәйн зур хөкемдарлыкка ия иде)! Аның белән булганнарны Без гыйлем белән уратып алган идек»** («әл-Кәһф», 89–91).

Хәзрәти Зөлкәрнәйннең, төрле илләрне бер-бер артлы яулап, көнчыгышка таба барганлыгы, ахыр чиктә, цивилизацияле кавемнәр яшәгән өлкәләрнең тәмам беткәнлеге, үсешнең түбән, башлангыч баскычында (ялангач, йортсыз-җирсез) гомер итүче кабиләләр очравы, көнчыгышның иң ерак ноктасына барып җиткәнлеге аңлашыла.

Мондагы кешеләр кояш кыздыра башлагач, мәгарәләргә качалар яки диңгезгә чумалар. Ләкин кояшның көйдергеч эссесе кимегәч, мәгарәләреннән чыгып, тормышларын тәэмин итәр өчен, хезмәт куялар. Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм аларны да хак дингә өнди.

Соңыннан Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм төньякка таба сәфәр чыга. Анда чит телдә сөйләшкән бер кавемгә тап була һәм алар белән тәрҗемәче ярдәмендә сөйләшә.

Аллаһ Тәгалә:

ثُمَّ أَتْبَعَ سَبَبًا. حَتَّى إِذَا بَلَغَ بَيْنَ السَّدَّيْنِ وَجَدَ مِنْ دُونِهِمَا قَوْمًا لَا يَكَادُونَ يَفْقَهُونَ قَوْلًا

**«Шуннан соң ул янә бер сәбәп эзләде. Ниһаять, ике тау арасына ирешкәч, алар алдында һич сүз аңламаган бер кавемгә тап булды»**, – дип әйтә («әл-Кәһф», 92–93).

Хәзрәти Зөлкәрнәйн очраткан бу бәндәләр аңа Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ исемле мәхлукларның үзләрен гел бимазалап торуына зарлана һәм Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәмгә әлеге мәхлуклардан сакларлык бирәр дивар салу үтенечен җиткерәләр. Шуннан соң Зөлкәрнәйн дивары корыла. Әлеге кавем дә, һидаят юлына өстенлек биреп, мөселманга әверелә. Аяти кәримәләрдә болай дип бәян ителә:

قَالُوا يَا ذَا الْقَرْنَيْنِ إِنَّ يَأْجُوجَ وَمَأْجُوجَ مُفْسِدُونَ فِي الْأَرْضِ فَهَلْ نَجْعَلُ لَكَ خَرْجًا
عَلَى أَنْ تَجْعَلَ بَيْنَنَا وَبَيْنَهُمْ سَدًّا. قَالَ مَا مَكَّنِّي فِيهِ رَبِّي خَيْرٌ فَأَعِينُونِي بِقُوَّةٍ أَجْعَلْ
بَيْنَكُمْ وَبَيْنَهُمْ رَدْمًا. آتُونِي زُبَرَ الْحَدِيدِ حَتَّى إِذَا سَاوَى بَيْنَ الصَّدَفَيْنِ قَالَ انْفُخُوا حَتَّى
إِذَا جَعَلَهُ نَارًا قَالَ آتُونِي أُفْرِغْ عَلَيْهِ قِطْرًا. فَمَا اسْطَاعُوا أَنْ يَظْهَرُوهُ وَمَا اسْتَطَاعُوا لَهُ
نَقْبًا. قَالَ هَذَا رَحْمَةٌ مِنْ رَبِّي فَإِذَا جَاءَ وَعْدُ رَبِّي جَعَلَهُ دَكَّاءَ وَكَانَ وَعْدُ رَبِّي حَقًّا

**«Әйттеләр: “И, Зөлкарнәйн, бу туфракта Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ бозыклык кыла. Сиңа бер хак түләсәк, алар белән безнең арада бер дивар төземәссеңме?”» (Ул җавабында) әйтте: «Раббым миңа биргән нәрсәләр хәерлерәк. Сез миңа көчегез белән ярдәм итегез, сезнең белән алар арасында нык бер койма ясармын. Миңа тимер кисәкләре китерегез». Ниһаять, ике тау арасын (тимер кисәкләре тутырып, аларны) тигезләгәч: «Өрдерегез!» – диде. Нәтиҗәдә аны ут хәленә китергәч: «Өстенә кояр өчен, миңа эрегән бакыр китерегез», – диде. (Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ) Аңа менә дә алмадылар һәм тишә дә алмадылар. (Зөлкәрнәйн) әйтте: «Бу – Раббымнан бер рәхмәт. Әмма Раббымның вәгъдәсе җиткәч, Ул моны җир белән тигезләячәк. Раббымның вәгъдәсе хак (һичшиксез, чынга ашачак)»** («әл-Кәһф», 94–98).

Зөлкәрнәйн диварының җимерелүе кыямәт галәмәтләренең берсе дип санала. Бу дивар хәзерге Бөек Кытай дивары түгел. Аның кайда булуы турында фикерләр төрле. Дивар кыямәт якынайгач, ишеләчәк һәм Яэҗүҗ белән Мәэҗүҗ кавемнәре, җир йөзенә таралып, коткы, фетнә кубарачак.

**Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ кавеме**

Риваятьләргә күрә, Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ бик әшәке һәм зыян салучы халык була. Йөзләре яссы, күзләре кечкенә, колаклары зур, буйлары кыска. Күп санлы булулары белән аерылып тора. Кыямәт килер алдыннан җир йөзенә таралачаклар. Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ кавемендә балалар бик тиз туып, алар бик нык үрчи башлаячак. Калдык-постык өстендә чебеннәр ничек тиз үрчесә, болар да шулай күбәячәк. Хәзер алар яшәгән урын Хак Тәгалә тарафыннан яшеренгән.

Вакыты җиткәч, Зөлкәрнәйн дивары җир белән тигезләнәчәк һәм бу кавем дөньяга таралачак. Бары Мәккәи Мөкәррәмә, Мәдинәи Мөнәввәрә һәм Иерусалимга гына керә алмаячаклар. Бу изге калалардан кала, һәр җиргә өлгерәчәкләр. Үзләре килгән җирләрдә ашап-эчеп, һәрнәрсәне корытачаклар һәм тирә-юньне бозыклыкка күмәчәкләр. Саранча кебек үрчеп, төрле хәшәрәтләр кебек зыян салачаклар. Ахыр чиктә, Аллаһ аларны һәлак итәчәк.

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез әйткән:

*«(Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм салган диварны) көн саен чокыйлар, уялар. Инде тишеп чыгарыр дәрәҗәгә җиткәндә, башлыклары: "Калдырыгыз, иртәгә тишәрбез", – дип әйтер. (Алар калдырып киткәч), Аллаһ диварны тагын да ныклырак итеп, элекке хәленә кайтара. Шул рәвешле көн артыннан көн узар, аларга бирелгән срок тулар да үзләренең кешеләргә бәла китерәчәкләре максат итеп куелган вакыт килер. Шулчак башлыклары: "Әйдәгез, кайтыгыз! Иртәгә, иншә Аллаһ, диварны тишәрсез", – дип әйтер. Шунда ул беренче тапкыр "иншә Аллаһ" гыйбарәсен телгә алыр».*

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сүзен болай дип дәвам итә:

*«Ул көнне кайтып китәрләр. Иртәгесе көнне килгәч, диварны эш көне ахырында нинди хәлдә калдырып китсәләр, шул хәлендә күрерләр һәм тәмам тишеп үтәрләр. Шул тишек аша кешеләр өстенә чыгарлар. (Каршыларына очраган) суларны эчеп, аларны корытырлар. Кешеләр алардан куркып качар. Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ күккә бер ук атып җибәрер. Бу ук канга буялып кире үзләренә кайтыр. Шуннан соң: "Җир йөзендә булганнарны таптый-таптый издек, күктәгеләрне дә, түбән төшереп, җиңдек", – дип әйтерләр.*

*Аллаһ аларны иңсәләреннән эләктереп алачак бер корт җибәрер. Бу корт аларның барысын да һәлак итеп, һәркайсын кисәкләргә ваклап, җиргә чәчер. Мөхәммәднең җанын кулында тотучы Зат белән ант итәм, җир йөзендәге*

*бөтен хайваннар да шуларның итен ашап, тернәкләнер, сөтләнер һәм симерер»* (Тирмизи, «Тәфсир», 18/6; Ибне Мәҗә, «Фитән», 33/4080).

Габдуллаһ ибне Мәсгуд радыйаллаһу ганһе болай дип тапшырган:

*«Мигъраҗ кичәсендә Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Хәзрәти Ибраһим, Хәзрәти Муса һәм Хәзрәти Гайсә белән очраша. Алар үзара кыямәт турында сөйләшәләр. Әүвәл Хәзрәти Ибраһим галәйһис-сәләәмнән башлап, кыямәт турында аннан сорыйлар. Ул кыямәт хакында бернәрсә дә белми. Аннары Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәмнән сорыйлар. Кыямәт турында ул да һични әйтә алмый. Чират Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәмгә җитә. Ул: "Кыямәт кубар алдыннан барлыкка киләчәк нәрсәләр (галәмәтләр) турында миңа мәгълүмат бирелде. Әмма кыямәт кубачак вакытны Аллаһтан башка һичкем белә алмас", – ди. Аннары (кыямәт билгеләреннән берсе буларак) Дәҗҗалның чыгуы турында сөйли:*

*"Соңыннан мин күктән иңеп, аны үтерәчәкмен һәм шуннан халыклар үз илләренә кайтачак. Бу юлы аларның каршына Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ кавеме чыгачак һәм тау түбәсеннән бик тиз һөҗүм итәчәк. Бу кавем юлларында очраган һәр суны эчеп бетереп барачак, кул астына эләккән һәрнәрсәне ватып-җимереп үтәчәк. Шулчак халык зар-интизар белән Аллаһтан ярдәм сораячак. Мин дә, Яэҗүҗ белән Мәэҗүҗ үтерелсен өчен, Аллаһка дога кылачакмын. Җирдән аларның исе аркасында бик сасы ис киләчәк. Бу истән котылу өчен, кешеләр Аллаһка дога кылачак. Мин дә Аллаһка ялварачакмын. Аллаһ Тәгалә исә күктән бер су җибәрәчәк һәм шул су ул кавем калдыкларын диңгезгә алып китәчәк. Соңыннан таулар кечерәйтелеп, таралачак һәм, тире җәелеп киңәйтелгән кебек, җир дә шулай җәеп киңәйтеләчәк. Менә шушы мин сөйләгән хәл чынга ашкач, кыямәтнең кешеләргә, кайчан бала табачагы билгеле булмаган йөкле хатынның хәле шикелле, якын (ягъни һәр мизгелдә башларына төшәргә мөмкин) булачагы белдерелде"».*

Әлеге хәдисне тапшырган кешеләрдән әл-Гаввам бу вакыйгаларның Коръәни-Кәримдәге:

حَتَّى إِذَا فُتِحَتْ يَأْجُوجُ وَمَأْجُوجُ وَهُمْ مِنْ كُلِّ حَدَبٍ يَنْسِلُونَ

**«Ниһаять, Яэҗүҗ вә Мәэҗүҗ (диварлары) ачылганчыга кадәр, алар биек урыннан ябырылачаклар»**, – аяти кәримәсе («әл-Әнбия», 96) белән дә расланганын искә ала (Ибне Мәҗә, «Фитән», 33/4081).

Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ һәлак ителгәннән соң, кешеләрнең сау-сәламәт, иминлектә булачагын һәм гыйбадәтләрен дәвам итәчәген Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Бу Бәйткә (Кәгъбәгә) Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗтән соң да хаҗ белән гомрә кылыначак»*, – дигән сүзләр белән белдергән (Бохари, «Хаҗ», 47).

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм башка бер хәдис-шәрифендә әлеге залим кавемнең җәһәннәмгә ыргытылачагы турында хәбәр итә.

Әбү Сәгыйд радыйаллаһу ганһе риваятенә күрә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә:

*«Газиз һәм Җәлил булган Аллаһ кыямәт көнне: "Әй, Адәм!" – дип дәшәр. Адәм галәйһис-сәләәм: "Боер, Раббым! Синең әмереңне тыңлыйм, бөтен хәерле нәрсәләр Синең кулыңда!" – дип әйтер. Адәм галәйһис-сәләәмгә мондый аваз ирешер: "Аллаһ сиңа җәһәннәм әһлен чыгарырга куша!" Адәм галәйһис-сәләәм: "И, Раббым! Җәһәннәм әһле күпме соң?" – дип сорар. "Һәр мең бәндәдән тугыз йөз туксан тугызы!"*

*Йөкле хатыннарның баласы төшкәнен, балалар картайганын, кешеләрнең исерек булмаган килеш тә, газап дәһшәтеннән исергәнен күрәчәгең вакыт әнә шул вакыт инде».*

Бу хәбәр әсхабе кирамны бик кайгыга сала. Аларның йөзләре үзгәреп китә. Әфәндебез сүзен болай дип дәвам итә:

*«Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗтән – меңнең тугыз йөз туксан тугызы, сездән исә (меңнән) бер (җәһәннәмгә керәчәк). Шуны да белегез: сез кешеләр арасында ак үгездә бер кара төк яки кара үгездә бер ак төк кадәр»* (Бохари, «Тәфсир», 22/1, «Әнбия», 7).

Галәмнәр горурлыгы булган Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтен бөтен төрле фетнәләр турында кисәтеп куя, аерым алганда, Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ бәласе турында кисәтү ясый.

Зәйнәб бинте Җаһш радыйаллаһу ганһүмә сөйләгәннәрдән:

«Рәсүлүллаһ галәйһис-саләтү вәс-сәләәм бүлмәгә беркөнне бик куркыныч кыяфәт белән керде дә: *"Лә иләһе илләллаһ, якынлашып килгән бәла аркасында гарәпләргә нинди кайгы!* (Баш бармагы белән имән бармагыннан боҗра ясап күрсәтеп) *бүген Яэҗүҗ һәм Мәэҗүҗ диварыннан менә шундый бер тишек ачылды"*, – дип әйтте. Мин: "И, Аллаһның Рәсүле, арабызда изге затлар булган хәлдә дә, барыбыз бергә һәлак ителәчәкбезме?" – дип сорадым. *"Әйе, әшәкелекләр артса, шулай булыр!"* – диде» (Бохари, «Әнбия», 7; Мөслим, «Фитән», 1/2880).

Хәдис-шәрифтә: *«Якынлашып килгән бәла аркасында гарәпләргә нинди кайгы!»* – дигәндә, *«гарәп»* сүзенең телгә алынып, башка милләтләр әйтелмәвенең хикмәте ул вакытта бөтен мөселманнарны гарәпләр тәшкил итүе белән бәйле. Бу күзлектән караганда, әлеге кисәтү бөтен мөселман җәмгыятьләрен колачлый. Кайбер галимнәр фикеренчә, *«якынлашып килгән бәла»* сүзтезмәсендә Хәзрәти Госман радыйаллаһу ганһенең үтерелүе белән бергә өммәт эчендә башланачак фетнәләр күздә тотыла. Һәм бу фетнәләр Яэҗүҗ

белән Мәәҗүҗ диварында матди һәм рухи тишек барлыкка килүгә сәбәп булачак кабул ителә.

### Хәзрәти Зөлкәрнәйннең гыйбрәтле һәм хикмәтле кыйссаларыннан

Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм үзенең бер сәфәрендә үзенчәлекле кавем очрата, бу кавем халкы, үлем турында борчылып, нәфесләрен һәрдаим тыярга тырыша. Анда кешеләрнең дөнья байлыгы – алтын-көмеш ише нәрсәләре бөтенләй булмый. Кавем кешеләре яшелчәләр белән туклана. Яшелчәләрен бик тырышып саклыйлар. Бу кавемдә һәркем, үзенә кабер казып куеп, аны һәр көн чистарта һәм гыйбадәтләрен дә шунда башкара. Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм боларның хөкемдарларын чакырта. Хөкемдар зат: «Мин берәүне дә сорамадым. Мине күрергә теләгән кеше яныма үзе килер!» – дип белдерә. Бу җаваптан соң ул хөкемдар янына барып, Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм: «Мин сине чакырган идем, ник килмәдең?» – дип сорый. Хөкемдар: «Сиңа мохтаҗ түгелмен, ихтыяҗым булса, килер идем», – дип җавап бирә. Шуннан соң Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм: «Сездә нинди хәл бу? Сездәге гадәт-тәртипне башка һичкемдә күргәнем юк!» – дип кызыксынгач, хөкемдар: «Әйе, без алтын-көмешне зурламыйбыз. Чөнки шуны күрдек, берәрсенең кулына алардан бер өлеш керсә, икенче юлы тагын да күбрәк алырга теләп, тынычлыгы бозыла... Шуңа күрә дөнья малы артыннан кумыйбыз», – дип аңлата.

Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм: «Нинди каберләр бу? Аларны ник казыйлар, ник гыйбадәтләрне шунда үтиләр?» – дип сорый.

Хөкемдар: «Дөньялыкка бирелмәс өчен, моны әнә шулай эшләдек. Каберләрне күреп, көннәрнең берендә шунда керәчәгебезне хәтерләгәч, һәрнәрсәдән ваз кичәбез», – дип әйтә.

Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм: «Ник яшелчәдән башка нәрсә ашамыйсыз? Терлек асрыйсыз, итен-сөтен куллансагыз ярамасмыни?» – дип кызыксына.

Хөкемдар: «Ашказаннарыбызның хайваннар өчен кабер булуын теләмибез. Яшәешебезне үсемлекләр белән тәэмин итәбез. Чөнки бугаздан аска төшкәч, без инде бер ризыкның да тәмен татый алмыйбыз!» – дип җавап бирә.[89]

Хәзрәти Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәмнең тагын бер кыйссасы түбәндәгедән гыйбарәт:

Берәү Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәмгә: «Миңа иманымны һәм «якыйн»ымны[90] ныгытачак берәр нәрсә өйрәт әле», – дип мөрәҗәгать итә.

89. Чынлыкта Аллаһ Тәгалә хәләл кылган хайваннарның итен ашауның һичбер гаебе юк. Монда ул кавем үзе өстенлек биргән бер үзенчәлек турында сүз бара.

90. Якыйн – шик-шөбһәдән котылган, дөрес, нык һәм анык белем; һичшиксез инану һәм тулы ышаныч.

Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм җавабында әйтә: «Ачуланып, үпкәләп, бирәүгә дә кызма! Чөнки шайтанның кешегә иң еш керә торган мизгеле – ачу-нәфрәт вакыты. Ашыгудан тыел! Ашыкканда, үзеңә насыйп ителгәнне юкка чыгарырсың. Якын һәм ерак һәркемгә карата мөлаем бул! Киребеткән, инкярчы һәм залим булма!» – дип җавап бирә.

Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм үләр алдыннан мондый васыять калдыра:

«Мине юыгыз, кәфенләгез! Аннары бер колашага куегыз! Бары кулларым гына тышка чыгып, асылынып калсын! Хезмәтчеләрем артымнан барсын! Хәзинәләремне дә качырларга төягез! Халык минем шундый зиннәтле солтанлыгыма һәм дөнья малына хуҗа булуыма карамастан, кабергә буш кул белән китүемне, хезмәтчеләремнең дә, хәзинәләремнең дә бу дөньяда калуын, минем белән бергә китмәгәнен күрсен! Бу ялганчы һәм вакытлы дөньяга алданмасыннар!..»

Ул сөйләгәннәр нәкъ шулай эшләнә. Галимнәр бу васыятьне түбәндәгечә аңлата:

«Минем арттан барган шушы гаскәрләр белән Шәрыктә һәм Мәгърибтә хаким булдым. Кул астымда бик күп хезмәтче һәм бихисап гаскәр бар иде. Һичкайсы минем кушканнан тайпылмады. Дөнья башыннан ахыргача миңа буйсына иде. Хисапсыз хәзинәләргә ия булдым. Әмма дөнья нигъмәтләре мәңгелек түгел. Менә, сез күргәнчә, дөнья малы дөньяда калды, каберемә буш кул белән китәм! Сез ахирәттә файдалы булган гамәлләр кылыгыз!..»

Шулай ук Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә Хәзрәти Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм васыятендә сүз барган хакыйкатьне түбәндәгечә телгә ала:

*«Үлене (кабергә кадәр) өч нәрсә озата барыр: бала-чагасы, байлыгы һәм гамәле. Болардан икесе кайтып китәр, берсе калыр. Бала-чагасы һәм байлыгы кайтып китәр, гамәле (аның үзе белән) калыр»* (Бохари, «Рикак», 42; Мөслим, «Зүһд», 5).

Хәзрәти Зөлкәрнәйн көбә ясап сату белән шөгыльләнә, ризыгын маңгай тире белән эшләп таба. Ихтыяҗларыннан артып калганын исә Аллаһ юлына тота торган була.

Галәйһис-сәләәм!..

# ҖИҺАД ҺӘМ ӘМРИ БИЛ-МӘГЪРУФ (яхшылыкка өндәү)

Дөнья һәм ахирәт бәхетенә ирешергә теләгән мөэминнәр җаннарын, мал-мөлкәтләрен һәм Аллаһ аларга биргән бөтен нигъмәтләрне җитди максатларда һәм аларга ирешү өчен чара буларак кулланырга тиеш. Үлем һәм аннан соңгы тормыш турында уйлаган кеше өчен Аллаһ ризалыгына ирешүдән дә мөһимрәк максат була алмый. Коръәни-Кәримдә:

لَتُبْلَوُنَّ فِي أَمْوَالِكُمْ وَأَنْفُسِكُمْ...

*«Сез, һичшиксез, малларыгыз һәм җаннарыгыз белән сыналачаксыз...»* – дип әйтелә («Әли Гыймран», 186).

Шуңа күрә дә максатсыз кулланылган нигъмәтләрнең ахыры кайгы-газап булыр. Аяти кәримәдә әйтелә:

يَوْمَ لَا يَنْفَعُ مَالٌ وَلَا بَنُونَ. إِلَّا مَنْ أَتَى اللَّهَ بِقَلْبٍ سَلِيمٍ

*«Бер малның да, улларның да файда бирмәгән көнне. Мәгәр керсез күңел белән Аллаһка килүче булмаса гына (файда табар)»* («әш-Шугара», 88–89).

Бәндәгә бирелгән нигъмәтләр, ваемсызлык һәм наданлык аркасында кулдан-кулга күчсә, шәхес өчен һәм җәмгыять өчен кайгы-борчулар алып килер, тынычлыкны бетерер. Әгәр сәламәт йөрәк белән эш йөртсә, бәндәләр үзләрен дөнья җәннәтендә дип күрерләр. Җәмгыятьтә тынычлык һәм бәхет урнашыр.

Әбү Сәгыйд әл-Худри радыйаллаһу ганһе риваять кыла:

Беркөнне Рәсүл Әкрәм Әфәндебездән: «Йә, Рәсүлүллаһ, иң фазыйләтле кеше кем ул?» – дип сорыйлар. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Аллаһ юлында малы һәм җаны белән җиһад кылучы – мөэмин кеше!»* – дип әйтә (Бохари, «Җиһад», 2; Мөслим, «Имарәт», 122, 123).

Бүтән хәдис-шәрифтә: *«Чын мөҗаһид – нәфесенә (теләк-омтылышларына) каршы җиһад алып баручы ул»*, – дип әйтелә (Тирмизи, «Фәдаилүл-Җиһад», 2/1621).

Мөэминнең бәхетле җиңүе иман һәм файдалы гамәлләргә нигезләнә. Чын мөэминнең кулыннан һәм теленнән өммәте файда күрә.

Сәхабәләрдән Мусгаб ибне Гомәйр радыйаллаһу ганһенең хәленә кызыкмый мөмкин түгел. Мәккәдә күп кенә матди мөмкинлекләре булуга кара-

мастан, аларны югалту куркынычы барлыгын да белә торып, ул яшь чагында ук мөселманлык кабул итә. Мусгаб ибне Гомәйр радыйаллаһу ганһе ата-анасының аны мирастан мәхрүм итү кебек янауларына игътибар бирми һәм исламнан баш тартмый, куылган, фәкыйрь зат булып, Мәдинәи Мөнәввәрәгә һиҗрәт кыла. Анда җиң сызганып дәгъват эшенә керешә һәм бик күп кешенең һидәяткә ирешүенә сәбәп була.

Мусгаб радыйаллаһу ганһе Өхед сугышында Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне саклаганда шәһид китә. Шуннан соң фәрештәләрнең берсе, Мусгаб рәвешенә кереп, ул күтәреп барган байракны кулына күтәреп ала, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә, Мусгабның шәһид үлеменнән хәбәрдар булмыйча, байракчыга дәшә: *«Алга бар, әй Мусгаб!»* Шуннан соң фәрештә Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә таба карый. Әнә шулчак аның бер фәрештә икәнлеген абайлаган Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мусгабның шәһид китүен аңлап ала.

Соңыннан Мусгаб ибне Гомәйрнең мөбарәк җәсәденә юлыгалар, ләкин әлеге изге шәһидне төрерлек бер кәфен дә табылмый. Мусгаб ибне Гомәйр Коръәни-Кәримдә түбәндәге күркәм аять белән мактап телгә алынган юмарт зат була:

مِنَ الْمُؤْمِنِينَ رِجَالٌ صَدَقُوا مَا عَاهَدُوا اللَّهَ عَلَيْهِ فَمِنْهُمْ مَنْ
قَضَى نَحْبَهُ وَمِنْهُمْ مَنْ يَنْتَظِرُ وَمَا بَدَّلُوا تَبْدِيلًا

**«Мөэминнәр арасында Аллаһка биргән сүзләрендә торган ирләр бар. Аларның кайсылары биргән вәгъдәсен үтәде (җанын бирде). Кайсылар исә (шәһидлеккә ирешүне) көтә. Алар бернинди дә үзгәртү белән (биргән сүзләрен) үзгәртмәделәр»** («әл-Әхзәб», 23).

Аллаһ Тәгалә тагын болай диде:

إِنَّ اللَّهَ اشْتَرَى مِنَ الْمُؤْمِنِينَ أَنْفُسَهُمْ وَأَمْوَالَهُم بِأَنَّ لَهُمُ الْجَنَّةَ يُقَاتِلُونَ فِي سَبِيلِ اللَّهِ
فَيَقْتُلُونَ وَيُقْتَلُونَ وَعْدًا عَلَيْهِ حَقًّا فِي التَّوْرِيةِ وَالْإِنْجِيلِ وَالْقُرْآنِ وَمَنْ أَوْفَى بِعَهْدِهِ
مِنَ اللَّهِ فَاسْتَبْشِرُوا بِبَيْعِكُمُ الَّذِي بَايَعْتُمْ بِهِ وَذٰلِكَ هُوَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ

**«Һичшиксез, Аллаһ, җәннәт бәрабәренә, иман китерүчеләрдән җаннарын һәм малларын сатып алды. (Алар) Аллаһ юлында сугышалар, үтерәләр һәм үтереләләр. Тәүратта да, Инҗилдә дә, Коръәндә дә Үзенә йөкләгән вәгъдә буларак. Сүзендә Аллаһтан да тугрырак кем бар? Ясаган алыш-бирешегезгә сөенегез. Бу – бик зур бер котылу!»** («Тәүбә», 111).

Әлеге аяти кәримәнең иңү сәбәбе тәфсирләрдә түбәндәгечә аңлатыла:

Акабә анты көнне җитмеш кеше Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ант иткәндә, Габдуллаһ ибне Рәваха: «Йә, Рәсүлүллаһ! Безгә Раббың һәм Синең хакыңа үтәргә тиешле һәртөрле шартны куя алырсың», – ди.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: *«Раббым өчен шартым – Аңа гыйбадәт кылуыгыз һәм һичнәрсәне Аңа тиңдәш куймавыгыз. Үземә килгәндә, Минем хакка үтәлергә тиешле шартым исә – җаннарыгызны һәм малларыгызны ничек сакласагыз, мине дә шулай саклавыгыз».* Әсхабе кирам: «Болай эшләсәк, безгә ни булыр?» – дип сорый. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм җавабында: *«Җәннәт булыр!»* – дип әйткәч, андагылар: «Нинди керемле алыш-биреш бит бу! Моннан һич тайпылмабыз, тайпылырга да теләмәбез!» – диләр (Ибне Кәсир, «Тәфсир», II, 406).

Сәхабәләрнең тормышы нәкъ менә җиһад, Аллаһ юлында тырышлык үрнәге булып тора. Аларның шәхесе Аллаһ Рәсүленең күңел тирәнлеге тәэсирендә формалаша. Дәрәҗәләренә күрә, алар Аллаһ Рәсүленең хис-кичерешләре белән хисләнәләр. Шунысы да игътибарга лаек: Хушлашу хаҗына 120 мең сәхабә катнаша. Шулкадәр сәхабәнең нибары 20 меңе генә Мәккәи Мөкәррәмә белән Мәдинәи Мөнәввәрәдә бакыйлыкка күчә. Башкалары исә исламга өндәү һәм Аллаһның сүзен өстен кылу (ислам динен күтәрү) өчен бөтен дөньяга тарала. Алар ахыргы барасы урыннары кабер икәнлеген белеп эш итә. Алар дин юлында рухи фазыйләт хакына җаннарын һәм малларын бирүдән һич тартынмый. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез алардан берәр дини максатта ярдәм сораганда, мал-байлыкларын һәм бар мөмкинлекләрен юмарт рәвештә сарыф итәләр. Хатын-кыз сәхабәләр дә алкаларын, беләзекләрен, муенсаларын салып, фидакярлек үрнәге күрсәтә.

Сүмәйя хатын ислам хакына җанын биреп, тәүге ислам шәһидәсенә әверелә. Хәзрәти Госман радыйаллаһу ганһенең гаиләсе асылташларын Аллаһ юлына сарыф итә. Гомәр ибне Габделгазиз хәлифә вазифасына билгеләнгәч үк, хатыны бөтен байлыгын казнага тапшыра.

«Сәгатүл-гусрә» (авырлык чоры) дип сыйфатландырылган Тәбүк сәфәре көннәрендә хатын-кыз сәхабәләр никадәр бизәнгечләре булса, барысын да Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм каршына алып килә. Унбер яшьләрдәге бер мөэминә кыз, сабый чагында колак йомшагына тагылган алкаларын салдыра алмагач, дулкынланудан, аларны колагын ертып тартып ала да шул канлы алкаларны Аллаһ Рәсүле каршына куя...

Хәзрәти Гайшә анабызның сеңлесе булган Әсманың соңгы вакытта күзләре күрми башлый. Аның улы Габдуллаһ ибне Зөбәйр Аллаһ юлында сугышка җыена һәм өстенә көбә кия. Әсма радыйаллаһу ганһә кулы белән улына кагылгач, аның көбә кигәнен аңлый да: «Улым, әллә син дә куркаклар кебек көбә кидеңме? Сал моны!» – ди.

Ханса хатын дүрт улы белән бергә Кадисия явында катнаша. Бәрелеш буласы көн алдыннан, кич ул балаларына мондый нәсыйхәт бирә: «Улларым! Сез үз теләгегез белән мөселман булдыгыз. Үз ниятегез һәм ихтыярыгыз белән ватаныгызны ташлап, монда килдегез… Сез белерсез ки, Аллаһ Тәгалә кяферләр белән көрәшкән мөэминнәргә никадәр зур әҗер-саваплар әзерли. Белеп торыгыз: мәңгелек ахирәт йорты фани булган дөньялыктагы өйдән хәерлерәк. Җәнабел-Хак әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اصْبِرُوا وَصَابِرُوا وَرَابِطُوا وَاتَّقُوا اللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ

**«И, иман китерүчеләр! Сабыр итегез, (дошманнарыгызга каршы) сабырлыкта ярышыгыз, (җиһад өчен) атларыгызны бәйдә тотып, чикләрне саклагыз һәм Аллаһтан куркыгыз, (Аның әмер һәм тыюларын тотып), бәлки, уңышка ирешерсез»** («Әли Гыймран», 200).

Ул очракта, иншә Аллаһ, иртәгәсе көнгә исән-сау аяк бассагыз, күзегезне ачып һәм Аллаһтан ярдәм сорап, дошманнарга каршы сугышка керегез. Әгәр бәрелешнең бик кызганын, көчәйгәнен күрсәгез, үзәгенә юнәлеп, дошман гаскәрләренең ачулы, дәһшәтле вакытында аларның башлыклары белән сугышыгыз. Шул очракта җиңү яулап, ганимәт алырсыз һәм олуг җәннәттә дә сый-хөрмәт күрерсез».

Икенче көнне иртән уллары аналарының бу нәсыйхәтен үтәп, яуга керә һәм батырларча сугышып, дүртесе дә берьюлы шәһид китә. Балаларының шәһид булуы турында хәбәр Ханса хатынга килеп ирешкәч, ул: «Мине улларымның шәһидлеге белән хөрмәтләгән Аллаһка мактаулар булсын. Бөек Раббымнан мине алар белән чиксез рәхмәтең булган җәннәтеңдә кавыштыруыңны сорыйм», – дип шөкер кылып, дога укый (Ибне Габделбәр, «әл-Истигаб», IV, 1827–29).

Мөселман булганчы, кардәшләренең үлеменә багышлап язган мәрсияләре белән танылган әлеге шагыйрь хатын Аллаһка иманның тәмен татыгач, үз балаларын тәэсирле, оста теле белән шәһидлеккә үгетли һәм йөрәк парәләренең дүртесенең дә берьюлы Аллаһ юлында шәһид китүләрен ишеткәч, Аллаһка хәмед-сәнәләр әйтә.

Югарыда искә алынган аналарыбыз – малларын-җаннарын Аллаһ юлына багышлаган искиткеч хатын-кызларга мисал булып тора.

Шуны яхшы төшенү зарур: Аллаһ юлында мал һәм җан белән җиһад кылуда максат кылыч белән сугышка күтәрелү дигән сүз генә түгел. Кылыч золымны бетерү, хаклыкны, гаделлекне тарату кебек зарурият очракларында кулланыла торган тимер кисәге генә. Төп җиңү – күңелләрне яулау ул.

Шулай ук Коръәни-Кәримдә кешеләрне һидәяткә ирештерү максаты белән **«Аллаһ юлында җиһад кылу»**га бәйле шактый күп аятьләр урын ала. Ләкин боларның бер өлешендә кайнар сугыш дип аталган сугыш турында сүз бара.

Анысы да зарурлык туганда гына. Исламда саклану яки илайы кәлимәтуллаһ, ягъни Аллаһ сүзенең өстенлеген күрсәтүдән кала, башка максатта сугышка урын юк. Бары территорияләр басып алу яки матди байлык яулау өчен генә алып барылган сугышлар – кешелекнең йөзен каралта торган золым ул. Асылда исламда сугыш һичшиксез хакыйкатьне тарату, һидәяткә ирешүгә нигез булу һәм золымны юкка чыгару кебек олуг сәбәп-максатларга гына нигезләнә ала. Чөнки Коръәндә болай диелә:

مَنْ قَتَلَ نَفْسًا بِغَيْرِ نَفْسٍ أَوْ فَسَادٍ فِي الْأَرْضِ فَكَأَنَّمَا
قَتَلَ النَّاسَ جَمِيعًا وَمَنْ أَحْيَاهَا فَكَأَنَّمَا أَحْيَا النَّاسَ جَمِيعًا

**«...Кем дә кем бер җан өчен яки җирдә бозыклык булмыйча, бер җанны үтерсә, гүя бөтен кешене дә үтергән кебек булыр. Кем дә кем аны (бер кешене) терелтсә, гүя бөтен кешеләрне терелткән кебек булыр...»** («әл-Маидә», 32).

Бу күзлектән караганда, кешелекне коткару өчен куелган бар тырышлык һәм хезмәтләр җиһадның бер өлеше булып тора.

«Тәүбә» сүрәсенең 103 нче аятендә әйтелә:

خُذْ مِنْ أَمْوَالِهِمْ صَدَقَةً تُطَهِّرُهُمْ وَتُزَكِّيهِمْ بِهَا
وَصَلِّ عَلَيْهِمْ إِنَّ صَلوتَكَ سَكَنٌ لَهُمْ وَاللّٰهُ سَمِيعٌ عَلِيمٌ

**«(И, Пәйгамбәр!) Малларыннан аларны пакьли һәм (пычрактан һәм гөнаһлардан) арындыра, (савапларын арттыра) торган сәдака (һәм зәкят) ал. Һәм аларга дога кыл. Һичшиксез, синең догаң – алар өчен бер тынычлану (борчу-газапларын баса). Аллаһ – Ишетүче, Белүче».**

Аяти кәримәдә: **«Сәдака ал!»** – дип кушылганнан соң, әсхабе кирам дәррәү инфак (Аллаһ юлында сарыф кылу) эшенә керешә. Һәркем бар булганын Аллаһ Рәсүле алдына китереп куя. Һичнәрсәсе булмаганнар исә таудан ташыган агачларны утынга кисеп яисә су ташып эшләгән акчаларын Аллаһ Рәсүленә алып киләләр. Матди һәм рухи көч-куәтләрен дөнья тормышының вакытлы ләззәтләренә әрәм-шәрәм итмичә, ахирәттә мескенлеккә төшүдән котылалар. Мал-мөлкәтнең чынлыкта Раббыныкы икәнлеген, бәндәнең бары билгеле бер вакыт өчен бу мөлкәтләрнең әманәтчесе генә була алганын аңлап яшиләр. Шушы кыска гына дөнья тормышын алар мәңгелек ахирәт бәхетенә ирешү мөмкинлеге өчен сарыф итәргә тырышалар.

Мәсәлән, беркөнне Тәбүк сәфәренә юл тотачак гаскәргә ярдәм җыела. Әнсарлардан Әбү Гакыйль радыйаллаһу ганһе дә бер күтәрәм хөрмә алып килә, тик чынлыкта ул ризыкка һәркемгә караганда да мохтаҗрак була:

«Йә, Рәсүлүллаһ! Ике күтәрәм хөрмә бәрабәренә төне буе сыртымда су ташыдым. Бер күтәрәмен гаиләмнең ихтыяҗлары өчен алдым, икенчесен исә Раббымның ризалыгын алу өмете белән Сиңа китердем!» – ди.

Рәсүл Әкрәм Әфәндебез: *«Аллаһ синең китереп биргәнеңне дә, алып калганыңны да бәрәкәтләндерсен!»* – дип әйтә һәм Әбү Гакыйль китергән хөрмәне ярдәм рәвешендә җыелган әйберләр арасына бушатырга куша (Табәри, «Тәфсир», X, 251). Гукбә ибне Гамр радыйаллаһу ганһе болай дип тапшыра:

«"Сәдака" аяте (ягъни «Тәүбә» сүрәсенең 103 нче аяте) иңгәч, аркабызда йөк ташып, эшләп алган акчабызны сәдака итеп бирә башладык. Шулчакта бер адәм килде дә күп итеп сәдака бирде. Монафыйклар: "Кеше күрсенгә шулай эшли", – диде. Башка берәү килеп, бер тотам хөрмәне сәдака итеп тапшырды. Монафыйклар янә сүзсез калмады: "Аллаһ моның бер тотам хөрмәсенә мохтаҗ түгел", – диделәр». Шуннан соң:

الَّذِينَ يَلْمِزُونَ الْمُطَّوِّعِينَ مِنَ الْمُؤْمِنِينَ فِي الصَّدَقَاتِ وَالَّذِينَ لَا يَجِدُونَ
إِلَّا جُهْدَهُمْ فَيَسْخَرُونَ مِنْهُمْ سَخِرَ اللَّهُ مِنْهُمْ وَلَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ

**«Алар үз ирекләре белән сәдака биргән мөэминнәр белән көчләреннән килгәнне генә биргәннәрне гаеплиләр һәм мыскыл итәләр. Аллаһ аларның бу мыскылларының җәзасын бирер. Аларга – тилмерткеч бер газап»**, – аяти кәримәсе («Тәүбә», 79) иңдерелде (Бохари, «Зәкят», 10; Мөслим, «Зәкят», 72).

Җиһадны кире кагучылар өчен түбәндәге хәдис-шәриф шулкадәр куркыныч кисәтү булып тора. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Миңа тормыш биргән Аллаһ белән ант итәм, сез йә яхшылыкка өндәрсез, яманлыктан тыярсыз, яки Аллаһ үз катыннан өстегезгә бер газап җибәрер һәм ул вакытта догада ялварырсыз, ләкин догагыз кабул ителмәс»*, – дип әйтә (Тирмизи, «Фитән», 9).

Димәк, хәерлегә һәм фазыйләткә өндәү вазифасыннан баш тарту илаһи газапның якынаюына сәбәп булачак. Мөэмин бәндәнең теленә хакыйкатьне, хаклыкны сөйләү килешә. Аятьләрдә һәм хәдисләрдә мөселманга, бер хата, ялгыш нәрсә күргәндә, дөреслекне алга чыгарырга кушыла. Аллаһ Тәгалә болай ди:

وَمَنْ أَحْسَنُ قَوْلًا مِمَّنْ دَعَا إِلَى اللَّهِ وَعَمِلَ صَالِحًا وَقَالَ إِنَّنِي مِنَ الْمُسْلِمِينَ

**«Сүз белән (кешеләрне) Аллаһка дәгъват итүче һәм изге гамәл кылган һәм: "Һичшиксез, мин мөселманнардан", – диючедән дә күркәмрәк (сүзле) кем бар?»** («Фуссыйләт», 33).

Рәсүл Әкрәм Әфәндебез дә өммәтен түбәндәгечә кисәтә:

*«Сездән нинди дә булса начар бер эш күргән кеше, аны үз кулы белән төзәтсен. Әгәр кулы белән төзәтергә көче җитмәсә, теле белән, аңа да көче җитмәгән кеше калебе белән эшләгән эшләре өчен аңа нәфрәт итсен, төзәлүе өчен дога кылсын. Монысы – иманның иң зәгыйфедер»* (Мөслим, «Иман», 78).

Теге дөньяда җәннәт һәм җәһәннәмнән кала башка сыеначак урын юк. Җаннарны, малларны һәм үзләренә бирелгән нигъмәтләрне ваемсыз рәвештә, нәфес кушкан юлда кулланучылардан Аллаһ Тәгалә: «Сиңа Рәсүлем килеп, хакыйкатьләрне төшендермәдеме? Сиңа мал биреп, нигъмәтләремне яудырмадыммы? Бу көн өчен үзеңә ни әзерләдең?» – дип шәхсән сораячак. Кеше әле уң ягына, әле сул ягына караячак – һичкем юк... Алга караячак, ә анда җәһәннәмнән башка берни дә күрә алмаячак...

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөйләгәннәрдән:

*«Кыямәт көнне бәндә (хисап тоту өчен Аллаһ хозурына) китерелер. Аллаһ Тәгалә: “Мин сиңа күз, колак һәм балалар бирмәдемме? Синең кулыңа хайваннарны һәм үсемлекләрне бирмәдеме? Сине аларга хуҗа итеп, алардан файдаландырмадыммы? Бу кыямәт көнендә Минем белән очрашу турында бер исеңә төшмәдеме?” – дип сораячак. Бәндә: “Юк”, – диячәк. Аллаһ Тәгалә Хәзрәтләре: “Алайса бүген Мин дә сине онытачакмын, нәкъ син (дөньяда) Мине оныткан кебек!” – дип әйтәчәк»* (Тирмизи, «Кыямәт», 6/2428).

Дөньялыктагы көннәрен һич санамыйча яшәгән бәндәләр әрәм иткән ул көннәре өчен үкенеч-кайгыда яначак. Бу дөньяда Аллаһ ризалыгына ирешә алмаганнарны үлемнән соң куркыныч җәһәннәм көтә. Имансыз рәвештә ваемсызлык белән капланган күзләр газаплы һәм куркыныч кабер караңгылыгында ачылачак.

Җәнабел-Хак аяти кәримәдә колларын кисәтеп куя:

وَلْتَكُنْ مِنْكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ اِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ
وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنْكَرِ وَاُولئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ

**«Арагызда хәергә чакыра, яхшы гамәлләрне әмер итә, начар гамәлләрдән тыя торган җәмәгать булсын. Менә шулар – (чыннан да) уңышка ирешүчеләр»** («Әли Гыймран», 104).

Бу аяти кәримәдә һәрдаим Хак Тәгаләгә иман китерергә өндәгән җәмәгатьнең булырга тиешлеге катгый рәвештә белдерелә. Ислам башлангыч чорында әсхабе кирамнан гыйбарәт иман сөрәнчеләре ярдәмендә таратылган кебек, соңыннан да аларның эзләренә басып барган, шуларга ияргән ихлас галимнәр, мөҗаһидләр һәм мөршидләр тырышлыгы белән дәвам итә. Җәнабел-Хак һәм Пәйгамбәр Әфәндебез андыйлар өчен бик күп әҗер-саваплар вәгъдә итә.

Әнәс радыйаллаһу ганһе ислам тәблигъчылары ахирәттә лаек булачак югары дәрәҗәләр турында хәбәр иткән хәдис-шәрифне тапшырган:

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркөнне болай дип әйтте: *«Сезгә кешеләрнең бер төрлесе турында хәбәр биримме? Алар пәйгамбәр дә, шәһид тә түгел. Ләкин кыямәт көнне пәйгамбәрләр һәм шәһидләр аларның Аллаһ каршындагы урыннарына кызыгырлар. Андыйлар нурдан гыйбарәт мөнбәрләр өстендә утырган булыр һәм һәркем аларны таныр»*. Әсхабе кирам: «Алар кемнәр соң, йә, Рәсүлүллаһ!» – дип сорадылар.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Алар – Аллаһның колларын Аллаһ тарафыннан сөйдергән һәм колларга да Аллаһны сөйдергән затлар. Җир йөзендә алар тәблигъчы һәм нәсыйхәтче булып йөрерләр»*. Мин: «И, Аллаһның Рәсүле! Аллаһны колларына сөйдерү турында аңладык. Ә Аллаһның колларын Аллаһка ничек сөйдертеп булыр?» – дидем.

Рәсүлүллаһ:

يَأْمُرُونَهُمْ بِمَا يُحِبُّ اللّٰهُ وَيَنْهَوْنَهُمْ عَمَّا يَكْرَهُ اللّٰهُ فَإِذَاأَطَاعُوهُمْ أَحَبَّهُمُ اللّٰهُ عَزَّ وَجَلَّ

*«Кешеләргә Аллаһ сөйгән нәрсәләрне яратырга кушарлар, Аллаһ сөймәгән нәрсәләрдән тыярлар. Кешеләр исә моңа буйсынгач, Аллаһ Газзә вә Җәллә аларны сөяр»*, – диде (Гали әл-Муттакый, III, 685–686; Бәйхакый, «Шугабүл-Иман», I, 367).

Ахирәт сәфәре өчен иң хәерле ризык – тәкъвалык. Бер мөэминнең иң хәерле көне – кичәгедән өстенрәк итеп уздырылганы. Ул очракта һәр көнне әүвәлге көнгә караганда күбрәк ахирәт ризыгы хәстәрләү өчен, бәрәкәтле кылырга тиешбез.

Бездән әүвәлгеләр килделәр, киттеләр, без дә күпмедер вакыттан соң аларның кәрванына кушылачакбыз. Йокыга киткән кебек үләчәкбез, уянган кебек кабат терелачәкбез. Соңыннан исә гамәлләребез турында хисапка тартылачакбыз. Ахирәтнең имин, махсус сайлап алынган, өстен урыннары тәкъва затлар өчен тәгаенләнәчәк. Барлык кайту, һәр агым бары тик Аллаһ Тәгаләгә таба.

Аллаһ Тәгалә йөрәкләребезне һәрдаим Үз ризалыгы һәм һидәяте юлында тотсын! Безне үзебездән, ягъни нәфесебез явызлыгыннан, аның зарарыннан сакласын!..

Амин!..

***Хәзрәти Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм***





ХӘЗРӘТИ

# Ягъкуб

*галәйһиссәләм*

*һәм*

ХӘЗРӘТИ

# Йосыф

*галәйһиссәләм*

***Мәхәббәт һәм хәсрәт утында көйдерелгән, сабырлык һәйкәленә әйләнгән***

# ХӘЗРӘТИ ЯГЪКУБ

***галәйһис-сәләәм***

***һәм***

***күпмедер вакыт коллык, соңыннан зинданда мең дә бер җәфа-газаптан соң Мисыр һәм күңелләр солтаны булган***

# ХӘЗРӘТИ ЙОСЫФ

***галәйһис-сәләәм***[91]

Исхак галәйһис-сәләәмнең улы булган Ягъкуб галәйһис-сәләәм Кәнан өлкәсендә яшәгән халыкка пәйгамбәр итеп җибәрелә. Аның Мәдйәндә яки Димәшкътә тууы риваять кылына. Хәзрәти Ягъкубның Гыйс атлы игезәге була, туганда Гыйстән соң дөньяга килгәнгә күрә, булачак пәйгамбәргә «иярүче, арттан баручы» дигән мәгънә белдергән Ягъкуб исеме бирелә.

Башка мәгънәсен карасак, «Ягъкуб» – «саффәтуллаһ» (Аллаһның саф һәм пакь кылган колы) дигән сүз. Ягъкуб галәйһис-сәләәмгә «Исраил» кушаматы тагыла. Ул сүз дә «Аллаһ колы» дигәнне белдерә.

Ягъкуб галәйһис-сәләәм нәселеннән күп кенә пәйгамбәрләр чыга. Хәзрәти Муса, Хәзрәти Һарун, Хәзрәти Давыт, Хәзрәти Сөләйман, Хәзрәти Зәкәрийя, Хәзрәти Яхья һәм Хәзрәти Гайсә галәйһимәс-сәләм нәсел-нәсәпләре белән Хәзрәти Ягъкубка тоташа, чөнки аның атасы Хәзрәти Исхак, «нәселеннән пәйгамбәрләр һәм маликләр чыксын өчен», дога кылган була.

Һәр пәйгамбәргә аңа гына хас бер дога бирелә, ул дога һичшиксез кабул ителә. Һәр пәйгамбәр бу доганы дөньялыкта вакытта укый, Пәйгамбәр Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә аны кыямәт көненә калдыра. Шуның ярдәмендә Рәсүлуллаһның олуг шәфәгате чынга ашар.[92]

Ягъкубның әнисе улын үзенең ир-ат бертуганы янына җибәрә. Ягъкубның агасының ике кызы була. Өлкәне – Ләйа, кечесе – Рахил исемле. Ягъкуб галәйһис-сәләәм агасына җиде ел хезмәт куя һәм аның олы кызы Ләйага өйләнә. Аннары тагын җиде ел агасына хезмәт итеп, кече кызы Рахилне дә хатынлыкка ала. Ягъкуб галәйһис-сәләәм табынган шәригатьтә бертуган ике кыз белән никахлашу рөхсәт ителә.

91. Бу бүлектә Йосыф галәйһис-сәлләм белән бәйле риваятьләрнең күбесе Исмаил Хаккы Бурсәвинең «Рухул-Бәян» исемле тәфсиреннән алынды.
92. Карагыз: Бохари, «Дәгъват», 1.

Ягъкубның агасы, кызларын аңа биргәндә, аларга хезмәтче итеп һәркайсына берәр җария дә бирә. Берсенең исеме Зүлфә, икенчесенеке Бәлхә була. Ягъкубка да ике җария бүләк ителә.

Хәзрәти Ягъкубның Ләйадан – алты, җарияләрдән – дүрт, Рахилдән ике улы туа. Рахилдән озак кына вакыт баласы булмый. Рахил, Аллаһ Тәгаләгә ялварып, дога кыла һәм аңа Йосыф насыйп ителә. Аннары Бүньямин туа. Аны табып, кырык көн узуга, Рахил җан тәслим кыла.

Хәзрәти Йосыф туган елны Ягъкуб галәйһис-сәләәмгә пәйгамбәрлек вазифасы йөкләнә. Ул кешеләрне тәүхид дингә өнди башлый. Аңа Кәнан төбәге халкыннан бик күпләр иман китерә.

Аллаһ Тәгалә аяти кәримәләрдә болай дип хәбәр итә:

وَوَهَبْنَا لَهُ إِسْحٰقَ وَيَعْقُوبَ وَكُلًّا جَعَلْنَا نَبِيًّا.
وَوَهَبْنَا لَهُمْ مِنْ رَحْمَتِنَا وَجَعَلْنَا لَهُمْ لِسَانَ صِدْقٍ عَلِيًّا

**«...Без аңа (Ибраһимгә) Исхакны һәм Исмәгыйльне бирдек, һәрберсен пәйгамбәр иттек. Без аларга рәхмәтебездән бирдек һәм алар өчен (телләрдә һәм диннәрдә) өстен һәм тугры бер мактау барлыкка китердек»** («Мәрьям», 49–50).

وَاذْكُرْ عِبَادَنَا إِبْرَاهِيمَ وَإِسْحٰقَ وَيَعْقُوبَ أُولِي الْأَيْدِي وَالْأَبْصَارِ. إِنَّا أَخْلَصْنَاهُمْ بِخَالِصَةٍ ذِكْرَى الدَّارِ. وَإِنَّهُمْ عِنْدَنَا لَمِنَ الْمُصْطَفَيْنَ الْأَخْيَارِ

**«(И, Рәсүлем! Диндә, гыйбадәттә һәм Аллаһ кушканнар мәсьәләсендә) көч һәм зирәклек ияләре булган колларыбыз Ибраһимне, Исхакны һәм Ягъкубны да искә ал. Һичшиксез, Без аларны ихласлык белән (ахирәт) йортын истә тотканнары өчен сайлап алдык. Һичшиксез, алар – Безнең хозурыбызда сайлап алынган колларыбыздан, хәерле кешеләрдән»** («Сад», 45–47).

Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дә бу пәйгамбәрләрнең фазыйләте турында телгә ала: *«Кәрим улы Кәрим улы Кәрим улы Кәрим; Ибраһим улы Исхак улы Ягъкуб улы Йосыф»* (Бохари, «Әнбия», 19, «Тәфсир», 12/1).

Йосыф галәйһис-сәләәм бар яктан да туганнарыннан аерылып тора. Әле сабый чагында ук әтисенең йөрәген яулап, аның мәхәббәтен казана, чөнки атасы Ягъкуб галәйһис-сәләәм улы Йосыфта үзендәге сыйфатларны күрә. Шунлыктан аңа бәйле өмет-теләкләре башка балаларыннан көчлерәк була. Әти кеше улын башкаларына караганда ныграк ярата һәм гел үзе янында йөртә.

Галәмдәге бөтен мәхлукларның күңел омтылышлары, уңай яки тискәре ниятләренә бәйле рәвештә, бер-берсенекеннән аерыла. Ләкин эгоизм, ягъни мәхлукның үз-үзенә тартылуы төп нигезне тәшкил итә. Шуңа күрә һәр мәхлук үзендәгеләр белән уртак сыйфатларны кемдә күрсә, шуңа тартылыр. Бу исә үзеңне башка берәүдә күрү һәм сокланып карау нәтиҗәсе булып тора, ягъни бер төрдәге мәхлуклар бер-берсен җәлеп итә, бер-берсенә тартыла. Мәхәббәт шытып чыккан икән, бу – сөйгәннең сөелгән затта үз сыйфатларын табуыннан килеп чыга.

Чыннан да, үзеңә тарту һәм тартылу өчен бергә булу һәм бертөрле булу шарт. Нәфескә буйсынган тормыш бозыкларны җәлеп итсә, рухи, иманлы хәят тугрыларны, изгеләрне җәлеп итәр; көферлек, наданлык – кяферне; тәрбиялелек, иршад исә туры юл күрсәтүче остазга ияргән затларны үзенә тартыр. Әлеге үзара тартылу законы матдәләрдә генә түгел, хәерлегә һәм явызлыкка тартылу рәвешендә рухи нәрсәләрдә дә бик анык күзгә ташлана.

**Йосыф кыйссасы – кыйссаларның иң матуры**

Йосыф галәйһис-сәләам кыйссасы Коръәни-Кәримдә «әхсәнүл-касас» (кыйссаларның иң матуры)[93] дип бәяләнә һәм аерым бер сүрә белән бәян ителә.

Аяти кәримәдә:

لَقَدْ كَانَ فِي يُوسُفَ وَإِخْوَتِهِ آيَاتٌ لِلسَّائِلِينَ

**«Һичшиксез Йосыфта һәм аның кардәшләрендә сораучылар өчен билгеләр (гыйбрәтләр) бар»**, – дип әйтелә («Юсуф», 7).

Йосыф кыйссасы, әлеге илаһи искәрмәдән аңлашылганча, гыйбрәтле һәм хикмәтле кыйсса булып тора. Йосыф кыйссасы һичбер китапта һәм әсәрдә Коръәни-Кәримдәге хәтле матур һәм нәфис өслүп белән бәян ителмәгән.

«Йосыф» сүрәсенең ахырында анык белдерелгәнчә, бу сүрәнең яшерен хәбәрләр белдерүе[94] һәм анда бернинди дә уйдырма булмавы,[95] акыл белән дә, башкаларның раславы белән дә шактый нигезле рәвештә ачыклана.

Чыннан да, Йосыф галәйһис-сәләамнең кыйссасы, анда салынган хикмәт һәм гыйбрәтләр җәһәтеннән, Коръәни-Кәримдәге игътибарны иң җәлеп итә торган кыйссаларның берсе санала. Мөфәссирләрнең бу кыйссадагы гыйбрәт тулы сәхифәләрдә тасвирланганнар хакында кайбер фикерләре, кыскача алганда, түбәндәгечә:

---

93. Әхсәнүл-касас – «иң күркәм рәвештә сөйләп бирү, иң матур кыйсса, хикәя, дини риваять» дигән мәгънәләр белдерә. «Кыйсса» сүзе нигездә күзәтеп-карап барырга лаеклы хәл, вакыйга мәгънәсендә кулланыла. Берәр хәбәр яки хикәянең кыйсса дип бәяләнүе аның күзәтеп, язылып барырлык кыйммәткә, шундый сыйфатка ия булуына бәйле.
94. Карагыз: «Юсуф» сүрәсе, 102.
95. Карагыз: «Юсуф» сүрәсе, 111.

1. Йосыф галәйһис-сәләәм кече яшендә үк башланган төрле-төрле бәла-казаларга каршы бик зур сабырлык күрсәткән.

2. Туганнарының шулкадәр җәфалауларына, әшәкелекләренә, хәтта үзен үтерергә маташуларына карамастан, Йосыф галәйһис-сәләәм алар белән очрашкач, гаҗәеп кече күңеллелек, кичерә белү үрнәге күрсәткән.

3. Бу кыйссада пәйгамбәрләр, изгеләр, фәрештәләр, шайтаннар, кешеләр, җеннәр, хайваннар, хөкемдарлар, дәүләтләр, сәүдәгәрләр, галимнәр, наданнар, ир-атлар, хатын-кызлар, хатын-кызларның төрле хәйлә-мәкерләре турында сөйләнә.

4. Бу кыйссада тәүхид, фикъһ, кеше тормышы, төш юрау, сәясәт, җәмгыять тормышы һәм дин белән дөньяның иминлеге өчен кирәкле бик күп мәсьәләләр турында сүз бара.

5. Җәфа-изалар, бәла-казалар һәм сынаулардан гыйбарәт тормыш юлының ахырында чиксез бәхеткә ирешү сурәтләнә.

Әйтик, Йосыф галәйһис-сәләәм утыз яшендә Мисыр патшасына әйләнә.

Йосыф галәйһис-сәләәм догасы ярдәме белән Зөләйха кабат яшьлегенә, чибәрлегенә кайта һәм аңа кияүгә чыга.

Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең Йосыфны югалту кайгысыннан елый-елый сукырайган күзләре янә күрә башлый.

Ягъкуб галәйһис-сәләәм иң яраткан улы, Бүньямин исә бертуганы Йосыф белән кавыша.

Йосыф галәйһис-сәләәм үзен үтерергә теләгән туганнарын кичерә, ә тегеләре, тәүбә итеп, изге затларга әйләнә.

Ягъкуб галәйһис-сәләәм һәм аның гаиләсе Кәнан иленнән Мисырга һиҗрәт кыла.

Йосыф галәйһис-сәләәмнең балачакта күргән төше чынга аша.

Мисыр патшасы Рәййан ибне Вәлид барлык дәүләт эшләрен Йосыф галәйһис-сәләәмгә тапшыра һәм аңа иман китереп, мөселманга әйләнә.

6. Йосыф галәйһис-сәләәм аңа кадәр һичкем укымаган иң матур доганы укый («Юсуф», 101)[96].

Һич шөбһәсез, иң матур кыйссалар тормышның үзеннән алынган, баштан узган вакыйгаларны сурәтләп бирер, ягъни теге яки бу кыйсса чын вакыйганың мәңгелек матурлыкларга юл күрсәткән тиңсез сүз-гыйбарәләр белән тасвирлануы һәм нәфис рәвештә бәян ителүенә бәйле рәвештә матураер, күркәмләнер. Чөнки чын матурлык һәрвакыт хыял-фантазиянең чикләрен

96. Карагыз: Куртуби, «әл-Җамигъ», IX, 120.

үтеп чыга һәм, шиксез матурлыктан берәр үрнәк чагылдырган очракта гына, ниндидер әһәмияткә ия була.

Йосыф кыйссасы Мөхәммәдкә хас матурлыкның камил бер тасвирламасы буларак иңдерелгән яшерен хикмәткә ия. Кыскасы, менә шундый үзенчәлекләре сәбәпле, ул «әхсәнүл-касас», ягъни кыйссаларның иң матуры санала.

Үбәй ибне Кәгъб радыйаллаһу ганһенең риваятенә күрә, Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм мондый нәсыйхәт биргән:

*«Колларыгызга "Йосыф" сүрәсен өйрәтегез! Чөнки кайсы мөселман, аны язып гаиләсенә һәм үз колына өйрәтсә, Аллаһ Тәгалә аның үлем алды исереклеген һәм газаплануларын җиңеләйтер. Һичбер мөселманнан көнләшмәс, моңа көч-тәкать таба алмас!»* (Зәмахшәри, «Кәшшаф», III, 98).

Йосыф галәйһис-сәләәм, туганнарының көнчелегенә дучар булып, коега ыргытыла, төрмәгә эләгү кебек авырлыклар кичерә. Тәкъвалыгы нәтиҗәсендә Җәнабел-Хак Йосыф галәйһис-сәләәм янына Җәбраил галәйһис-сәләәмне җибәрә. Аллаһ бик күп бүләк-игелекләр белән пәйгамбәрен юата. Бәла-казаларга каршы түзәргә көч бирә. Аннары куәт, бөеклек һәм солтанлык насыйп итә. Шул рәвешле Йосыф галәйһис-сәләәм, бик зур иза-җәфаларга дучар булуы аркасында, солтанлык елларында ярдәмгә мохтаҗ зәгыйфь бәндәләргә, фәкыйрьләргә һәм үз иленнән аерылганнарга тагын да мәрхәмәтлерәк мөнәсәбәт күрсәтә.

Шуны да белү кирәк: кем дә кем «Йосыф» сүрәсен укуын, андагы эчке мәгънәләрне аңларга тырышуын дәвам итә, шул Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм лаек булган сөенечтән үзенә өлеш алыр. «Йосыф» сүрәсе санап бетергесез хикмәт һәм гыйбрәтләр белән тулган. Әлеге сүрәдә пәйгамбәрлек, төш юрау, дөнья белән идарә итү, бәла-каза мизгелендә түземлек күрсәтеп, рухи балансны бозмыйча саклау, дошманның җәзаларына сабыр итү, якыннарыңнан аерылу, мәхәббәт, гашыйк зат, мәгъшук зат, хатын-кызларның хәйлә-мәкерләре, сынау, коллык, төрмә, котылу, бөеклек, кабул итү, бәхеткә тиенү, яманлыкка яманлык белән җавап бирергә көч җиткәндә дә гафу итү, нигъмәт, акылдан язу, ишарәт-билгеләр, сөенечле хәбәр, тәгъбир һәм тәфсир кебек күпме хикмәт һәм гыйбрәт тулы серләр яшеренгән. Шулай ук бу сүрәдә пәйгамбәрләрнең варислык мәсьәләсе, Аллаһның хәлифе булу серләре, җан һәм йөрәк кебек матди һәм рухи нәрсәләр турында да сөйләнә. Йосыф каршында Зөләйха нәфесне тыеп торуга үрнәк күрсәтә. Зөләйха мөселманга әйләнә, җанын тәрбияләп, Аллаһ ризалыгына ирештерәчәк дәрәҗәгә күтәрелә. Аннары җаны Йосыф белән бертуганнардай берләшә. Аллаһ хозурына барганчы, төрле авырлыклар, бәла-сынаулар белән үзен камилләштерә.

«Йосыф» сүрәсенең иңдерелү сәбәбе түбәндәгедән гыйбарәт:

«Яһүди галимнәре мөшрикләрнең башлыклары янына килеп: “Мөхәммәдтән сорагыз әле: Ягъкуб һәм аның гаиләсе ник Димәшкътән Мисырга күченде һәм Йосыф кыйссасы ни ул? “ – дип котырта.

Мөшрикләрнең башлыклары Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барып, әнә шул хакта сорый. Шуннан соң “Йосыф” сүрәсе иңдерелә» (Алуси, «Тәфсир», XII, 170).

Бу сүрә иңгән чорда Рәсүлуллаһ һәм мөэминнәр өстенә бер-бер артлы төрле авырлыклар, бәлаләр килгән була, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Хәзрәти Хәдичә анабызны һәм агасы Әбү Талибны югалта. Мөэминнәргә басым да шактый көчәя. «Кайгы елы» дип аталган бу вакытта әлеге сүрәнең иңүе Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм өчен дә, дәрәҗәле сәхабәләр өчен дә илаһи юату була. Чөнки бу сүрәдә Аллаһ юлында йөргән һәм сабыр иткән затлар өчен җиңүнең якын икәнлеге турында шатлыклы хәбәр җиткерелә.

«Йосыф» сүрәсенең тәүге аятьләрендә Җәнабел-Хак болай ди:

آلٓر تِلْكَ اٰيَاتُ الْكِتَابِ الْمُبِينِ. إِنَّا أَنْزَلْنَاهُ قُرْآنًا عَرَبِيًّا لَعَلَّكُمْ تَعْقِلُونَ.

**«Әлиф ләм ра. Бу – ап-ачык (һәрнәрсәне ачыклаучы) булган Китапның аятьләре. Һичшиксез, сез аңлар өчен, Без аны гарәпчә бер Коръән итеп иңдердек»** («Юсуф», 1–2).

Аяти кәримәдә «гарәпчә бер Коръән» дип, гарәп теленең телләр арасында иң камиле булганлыгын раслый. Мәгънә, сүз һәм яңгырашы ягыннан да Аллаһ Тәгаләнеке булганга күрә, Коръәни-Кәрим – искиткеч илаһи сәнгать шедевры. Әлеге илаһи могҗиза кыяматкә кадәр сакланачак, аңа охшашны бер мәхлук та һич иҗат итә алмаячак.

Аллаһ Тәгалә Коръәни-Кәримне гарәпчә иңдереп, бу телгә аерым бер хөрмәт насыйп итә. Коръәни-Кәримнең гарәпчә иңдерелүендә бер хикмәт Изге Китап җибәрелгән мохиткә хас сәбәпләрне юкка чыгарудан гыйбарәт. Әлбәттә, илаһи вәхи кешеләр сөйләшкән телләрдән берсендә килергә тиеш була. Чөнки бар галәм өчен универсаль булса да, һәр гамәлнең тәүге төше, һичшиксез, бер җирдә һәм бер рәвештә барлыкка килүе таләп ителә.

Алга таба аяти кәримәдә әйтелә:

نَحْنُ نَقُصُّ عَلَيْكَ أَحْسَنَ الْقَصَصِ بِمَا أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ هَـذَا الْقُرْآنَ وَإِنْ كُنْتَ مِنْ قَبْلِهِ لَمِنَ الْغَافِلِينَ

**«(Рәсүлем!) Без сиңа бу Коръәнне вәхи итүебез сәбәбе илә (үткәндәге өммәтләрнең хәбәрләрен) иң яхшы хикәяләү белән белдерәбез. (Шунысы хак:) моңа кадәр исә син хәбәрсез кешеләрдән идең»** («Юсуф», 3).

Бу сүрә – Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә кыйсса рәвешендә иңдерелгән тәүге сүрә. Сүз-гыйбарәләр ягыннан кыска, мәгънә ягыннан бик тирән һәм бай ул. Әлеге сүрәдә гыйбрәт ала белгәннәр өчен бик күп күркәм хикмәтләр, үзенчәлекләр һәм тирән мәгънәле сүзләр урын алган.

Йосыф галәйһис-сәләәм Хәзрәти Ягъкубның балаларыннан иң матуры була. Нәселе ягыннан да шундый ук дәрәҗәдә күркәм. Өч пәйгамбәр нәселеннән килеп, югары дәрәҗәгә лаек булган кебек, пәйгамбәрлек, чибәр йөз, төш юрау, дөнья белән идарә итү, кытлык һәм авырлык чорында халкына һәм якыннарына иң күркәм мөгамәлә күрсәтү шикелле өстен сыйфатлар белән дә хөрмәтләнә. Нинди зур һәм нинди матур бөеклек, затлылык. Йосыф галәйһис-сәләәмнең догасы да догаларның иң матуры була:

...تَوَفَّنِي مُسْلِمًا وَأَلْحِقْنِي بِالصَّالِحِينَ

**«...(Йә Раббы!) Мине мөселман буларак вафат иттер һәм изге кешеләр белән бергә ит!»**, – дип («Юсуф», 101), үлем аша Аллаһ белән кавышу турында иң беренче Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм сорый һәм шул хакта догада ялвара.

Шулай ук бу сүрәдә Йосыф галәйһис-сәләәм – йөрәкне, Ягъкуб галәйһис-сәләәм – җанны, Рахил – тәнне, Йосыфның унбер туганы исә нәфсани хисләрне чагылдыра. Коръәни-Кәрим кыйссаларына менә шундый бик нечкә, тиңсез мәгънәви үзенчәлекләр салынган. Әлбәттә, аларны тиешенчә күрә белү игътибарлылыкка, төпченүчәнлеккә бәйле.

**Хәзрәти Йосыфның төше**

Аяти кәримәдә болай диелә:

إِذْ قَالَ يُوسُفُ لِأَبِيهِ يَا أَبَتِ إِنِّي رَأَيْتُ أَحَدَ عَشَرَ كَوْكَبًا وَالشَّمْسَ وَالْقَمَرَ رَأَيْتُهُمْ لِي سَاجِدِينَ

**«Менә (бервакыт) Йосыф атасына әйтте: “И, этием! Һичшиксез, мин төшемдә унбер йолдыз, кояшны һәм айны күрдем. Аларны миңа сәҗдә кылган хәлдә күрдем”»** («Юсуф», 4).

Йосыф галәйһис-сәләәм төшендә күргән унбер йолдыз – туганнарын; кояш – атасы Ягъкуб галәйһис-сәләәмне, ә ай исә анасының апасы Ләйаны белдерә. Чөнки әнисе Рахил инде вафат була.

Йосыф галәйһис-сәләәмнең туганнарын йолдыз рәвешендә күрүендә хикмәт туганлыкка кеше тормышының барышына юнәлеш бирә торган мөһим факторлар салынудан гыйбарәт. Кояш һәм айның йолдызлардан соң телгә алынуы исә Йосыф галәйһис-сәләәмнең атасы һәм түтәсе белән туганнарыннан соңрак очрашачагына ишарәле.

Йосыф галәйһис-сәләәм бу төшне җиде яшендә күрә.

Бер яһүди Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына килә дә: «Йә, Мөхәммәд! Йосыфның нинди йолдызларны күргәнлеге турында миңа хәбәр бир», – дип, сорау белән мөрәҗәгать итә.

Рәсүлүллаһ бер мизгелгә тынып кала. Җәбраил галәйһис-сәләәм килеп, Аңа йолдызларның исемнәрен белдерә. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез, яһүдигә борылып: *«Әгәр сиңа бу хакта сөйләсәм, мөселман булырсыңмы?»* – дип дәшә.

Яһүди: «Әйе», – ди. Шуннан соң Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Болар – Җәрәйан, Тарыйк, Зәййал, Кабис, Амудан, Фәлик, Мысбах, Дарух, Фәраэ, Вәсаб, Залкәфитәйн. Йосыф төшендә менә шушы йолдызларның, кояшның һәм айның, күктән төшеп, үзенә сәҗдә кылганнарын күрде»*, – дип сөйләп бирә.

Шулчак яһүди: «Валлаһи, Син сөйләгән исемнәр дөрестер!» – дип раслый (Бурсәви, «Рухул-Бәян», IV т., 212–213 б.).

**Төшләр өч төрле була**

1. Җан-нәфес вакыйгалары. Кеше төшендә үз эш-гамәлләрен һәм иҗатын күрә яки гашыйк зат сөйгәнен күрә. Болар – кеше тормышының бер нәтиҗәсе;

2. Шайтанның куркытуы. Җанны борчуга салган буталчык һәм хаотик эчтәлекле төшләр турында сүз бара. Аларның мәгънәсе юк;

3. Аллаһтан килә торган хәбәрләр. Төш фәрештәсе кешегә Өммел-Китаптан бер нөсхә алып килеп, ләүхелмәхфуздә язылганнарны күрсәтер. Бу – чын төш, андыйларны «дөрес, садыйк төш» дип атыйлар. Болардан кала башка төшләр исә буталчык, аңлаешсыз була.

Дөрес төшләрне ләүхелмәхфуздән киләчәкне чагылдырган нур сызыгы дип атарга мөмкин.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Вакыты якынайган саен[97], мөэминнең төше беркайчан да диярлек ялган булмас (үзе күргәнчә чынга ашар). Мөэминнең (тугры) төше пәйгамбәрлекнең кырык алты җүзеннән берсе санала. Пәйгамбәрлектән килгән бернәрсә дә ялган булмас»* (Бохари, «Тәгъбир», 26; Мөслим, «Рүя», 6).[98]

---

97. Хәдис шәрехләүчеләр «вакыты якынаю» сүзтезмәсен «кыяматкә якын» яки «иртәнгә якын» (сәхәр вакыты) дип аңлата.
98. Дөрес төшнең пәйгамбәрлекнең кырык алтыдан бере икәнлеге болай аңлатыла: Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлеге 23 ел дәвам итә. Пәйгамбәрлекнең тәүге ике ае дөрес төшләр рәвешендә чынга ашканлыктан, бу вакыт (алты ай) егерме өч елның «кырык алтыдан берен» тәшкил итә.

Аяти кәримәләрдә болай дип әйтелә:

قَالَ يَا بُنَيَّ لَا تَقْصُصْ رُؤْيَاكَ عَلَى إِخْوَتِكَ فَيَكِيدُوا لَكَ كَيْدًا إِنَّ الشَّيْطَانَ لِلإِنْسَانِ عَدُوٌّ مُبِينٌ. وَكَذٰلِكَ يَجْتَبِيكَ رَبُّكَ وَيُعَلِّمُكَ مِنْ تَأْوِيلِ الْأَحَادِيثِ وَيُتِمُّ نِعْمَتَهُ عَلَيْكَ وَعَلَى آلِ يَعْقُوبَ كَمَا أَتَمَّهَا عَلَى أَبَوَيْكَ مِنْ قَبْلُ إِبْرَاهِيمَ وَإِسْحٰقَ إِنَّ رَبَّكَ عَلِيمٌ حَكِيمٌ.

**«(Атасы Ягъкуб галәйһис-сәләәм) әйтте: “И, улым! Төшеңне абыйларыңа сөйли күрмә, юкса, алар (көнчелекләре аркасында) сиңа тозак корырга уйларлар. Һичшиксез, шайтан – кешеләргә ап-ачык бер дошман. Болай булгач (төшеңдә күргәнчә), Раббың сине сайлаячак, сиңа (төшеңдә күргән) хәбәрләрнең мәгънәләрен юрауны өйрәтәчәк, сиңа да, Ягъкуб нәселенә дә, бабайларың Ибраһим һәм Исхакка биргән кебек, нигъмәтен бирәчәк. Һичшиксез, синең Раббың – (һәрнәрсәне) Белүче, Хикмәт иясе”»** («Юсуф», 5–6).

Йосыф галәйһис-сәләәм, уянып, төшен атасына сөйләгәч, атасы аның дөньялыкта һәм бакыйлыкта бик зур хөрмәткә һәм югары дәрәҗәгә ирешәчәген аңлап ала. Ул баласына төшен сер итеп сакларга, туганнарына сөйләмәскә куша. Югыйсә, туганнарының аңа көнләшеп, хәйлә, тозак корырга мөмкин икәнлеге турында әйтеп куя. Димәк, хөсетлектән генә түгел, хөсетлек корбаны булудан да саклану таләп ителә.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу мәсьәләдә болай дип кисәткән:

*«Ихтыяҗларыгызны канәгатьләндергәндә яшеренлекне кулланыгыз, чөнки һәр нигъмәт иясеннән көнләшерләр»* (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», I, 34).

**Көнчелек – йөрәкне үтерә торган ут**

Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең улларыннан Яһуда, Робил һәм Шәмгун әтиләренең Йосыфка аерым мөнәсәбәт күрсәтүендәге һәм аңа карата мәхәббәтендәге хикмәтне аңлый алмыйлар. Алар, көнләшеп:

إِذْ قَالُوا لَيُوسُفُ وَأَخُوهُ أَحَبُّ إِلَى أَبِينَا مِنَّا وَنَحْنُ عُصْبَةٌ إِنَّ أَبَانَا لَفِي ضَلَالٍ مُبِينٍ. اُقْتُلُوا يُوسُفَ أَوِ اطْرَحُوهُ أَرْضًا يَخْلُ لَكُمْ وَجْهُ أَبِيكُمْ وَتَكُونُوا مِنْ بَعْدِهِ قَوْمًا صَالِحِينَ

**«Әйттеләр: “Әлбәттә, Йосыф һәм карендәше (Бүньямин) әтиебезгә бездән сөеклерәк. Хәлбуки, без – (бер-беребезгә ярдәм итә торган көчле һәм зур) бер җәмәгатьбез. Һичшиксез, атабыз – ап-ачык бер ялгышлык эчендә. Йосыфны үтерегез яки аны билгесез (ерак) бер җиргә ташлагыз, шулчак атагызның йөзе сезгә генә юнәлер. Аның артыннан сез (тәүбә итеп) янә игелек ияләре булырсыз!”»** («Юсуф», 8–9).

Хәзрәти Ягъкуб улының төшеннән соң, Йосыфның пәйгамбәрлек эшен варис итеп алачагын аңлый, шуңа күрә аңа карата мәхәббәте тагын да көчәя. Ләкин бу хәлне сизгән бертуганнарның хөсетлеге көннән-көн арта. Шул дәрәҗәдә ки, бу көнчелек Йосыфка тозак коруларына китерә. Ягъни Ягъкуб галәйһис-сәләам сөю-мәхәббәтен арттырган саен, бу хисләргә карата тискәре мөнәсәбәт тә шулкадәр көчәя. Чөнки Җәнабел-Хак – «җәмигул-әздад», ягъни капма-каршы сыйфатларны үзендә берләштерә. Аның «اَلرَّقِيبُ», ягъни даими күзәтеп, тикшереп торучы һәм һәрвакыт өстен булучы мәгънәсендәге исем-сыйфаты бар. Шунлыктан артык сөю аерылуга китерә, чөнки Аллаһка мәхәббәт белән һичнәрсә тиңләшә алмый, Ул гына чиксез сөелүгә лаек.

Чыннан да Ягъкуб галәйһис-сәләам улы Йосыфның маңгаендагы пәйгамбәрлек нурын күрә, шунлыктан аңа карата артык игътибар күрсәтә. Аталарының әнә шул шәхси мәхәббәте, теләк-омтылышы Йосыфның башка туганнарында көнчелек тууга этәрә. Бер көн килеп, әлеге көнчелек савыты тулып ташый һәм туганнары Йосыфка каршы яман план кора.

Аятьтән сабак алынырга тиешле иң мөһим мәсьәлә – мәхәббәтне, көнчелеккә сәбәп булмасын өчен, күңелдә саклап тоту кирәклегендә. Сөю күңелдә булырга тиеш һәм аның хакында сөйләп йөрү урынсыз.

Йөрәк Аллаһ юлына юнәлтелмәсә һәм зикер белән пакьләнеп тормаса, карала һәм яманлыкка өндәүчегә әйләнә.

Аяти кәримәдә:

أَلَا بِذِكْرِ اللَّهِ تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ

**«...Күңелләр Аллаһны зикер итү белән генә тынычланмыймы?»** – дип әйтелә («әр-Рәгъд», 28).

Зикер – Аллаһны танып-белүнең йөрәктә аң-белем дәрәҗәсенә күтәрелүе ул. Әнә шундый хакыйкый зикер ярдәмендә генә йөрәк итагатьсезлектән котыла ала. Йөрәк – бәйтуллаһ (Аллаһ йорты) һәм мәхәббәтуллаһ (Аллаһка карата мәхәббәт) урыны ул. Әгәр анда зикергә урын юк икән, күпмедер вакыттан соң йөрәк нәфес теләкләренә буйсынып каралыр һәм ахырда үлем халәтенә килер.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Бер колның калебендә иман белән хөсетлек бергә булмас»*, – дип әйткән (Мөслим, «Имарәт», 130, 131/1891). Башка бер риваятьтә исә хөсетләнүчеләрнең хисапка тотылмыйча, турыдан-туры җәһәннәм утына атылачак затлар төркеменнән булганлыгы белдерелә.

Тәкәбберлек, комсызлык һәм хөсетлек бөтен гөнаһларның чишмә башы булып тора. Хәдис-шәрифтә көнчелекнең куркынычы турында болай дип аңлатыла:

*«Өч нәрсә бар, әнә шулар – бөтен гөнаһларның чыганагы; алардан һичшиксез сакланыгыз:*

*1. Тәкәбберлек. Иблисне нәкъ менә тәкәбберлек Адәм галәйһис-сәләәмгә сәҗдә кылмаска этәрә;*

*2. Комсызлык. Адәм галәйһис-сәләәмне җәннәттәге тыелган агачның җимешен ашарга комсызлык котырта;*

*3. Хөсетлек. Адәм галәйһис-сәләәмнең бер улының (Кабилнең) бертуганы (Һабилне) үтерүенә хөсетлек сәбәп була»* (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», I, 101).

Көнләшкән зат илаһи тәкъдиргә каршы килә, чөнки көнләшү Аллаһның башка берәүгә насыйп иткән нигъмәтнең, үзендә булмауны сылтау итеп, теге кешедә дә юкка чыгуын теләүне белдерә. Ләкин гыйбта (ак көнчелек) мондый түгел. Чөнки гыйбта – ак көнчелек очрагында кеше матди яки рухи нигъмәтнең үзендә дә, башкасында да булуын тели. Шул сәбәпле исламда гыйбта мактала, хуплана, ә хөсетлек катгый кире кагыла.

Хөсетлек көнләшелгән заттан бигрәк көнләшүченең үзенә зарар китерә. Моны башка берәүгә таш ыргытып, ул ташның кире үзенә кайтып күзен сукыraйткан кешенең хәле белән чагыштырырга мөмкин. Көнчелекнең ачу-нәфрәттән башка нәтиҗәсе юк, ахырда кешене оятка гына калдырыр, рисвай итәр. Әйтик, туганнарының Йосыф галәйһис-сәләәмнән көнләшүләре аркасында кылган яманлыклары ахырда үзләренә кире кайта.

Җәнабел-Хак түбәндәге аяти кәримә белән мөэминнәрне хөсетлектән тыя:

أَمْ يَحْسُدُونَ النَّاسَ عَلَى مَا آتَاهُمُ اللَّهُ مِنْ فَضْلِهِ

**«Әллә соң алар Аллаһ Үзенең фазылыннан кешеләргә биргән нәрсәләрдән көнләшәләрме?..»** («ән-Ниса», 54).

Рәсүл Әкрәм саллаллаһу галәйһи вә сәлләм мондый нәсыйхәт бирә:

*«Көнләшүдән сакланыгыз. Чөнки хөсетлек, ут утынны яндырып-ашап бетергән кебек, игеклекле гамәлләрне ашап бетерер»* (Әбү Давыт, «Әдәб», 44/4903; Ибне Мәҗә, «Зүһд», 22).

Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең Йосыфка карата артык көчле мәхәббәте Аллаһның хаклыкны саклау сыйфатына кагыла. Шул сәбәпле Аллаһ Тәгалә аңа бер сынау бирергә карар кыла һәм Йосыфны атасыннан аера. Чөнки бала кайбер очракларда ата кеше өчен бик зур имтихан булып тора. Мәсәлән, Нух галәйһис-сәләәм кяферләрнең һәлак ителүен сорап дога кылганда, мөшрик улының да суга батканын күргәч, сабырлыгын җуеп:

رَبِّ إِنَّ ابْنِي مِنْ أَهْلِي

**«…И, Раббым! Һичшиксез, улым бит – минем гаиләмнән…»** – дигән («Һуд», 45).

Нух галәйһис-сәләамнең бу үтенеченә Җәнабел-Хак болай дип җавап бирә:

قَالَ يَا نُوحُ إِنَّهُ لَيْسَ مِنْ أَهْلِكَ إِنَّهُ عَمَلٌ غَيْرُ صَالِحٍ

**«...И, Нух! Ул – синең гаиләңнән түгел. Һичшиксез, бу – килешле булмаган (начар, әшәке) бер гамәл…»** («Һуд», 46).

**Мәкерле план**

Ага-энеләре Йосыф галәйһис-сәләам белән бәйле уртак бер фикергә килгәч:

قَالَ قَائِلٌ مِنْهُمْ لَا تَقْتُلُوا يُوسُفَ وَأَلْقُوهُ فِي غَيَابَةِ الْجُبِّ يَلْتَقِطْهُ بَعْضُ السَّيَّارَةِ إِنْ كُنْتُمْ فَاعِلِينَ

**«Араларыннан берәве: “Йосыфны үтермәгез, әмма аны бер кое төбенә ташлагыз. (Һич булмаса) кәрваннарның берсе аны алыр. Әгәр (берәр) эш башкарасы кешеләр булсагыз”, – диде»** («Юсуф», 10).

Мондый тәкъдимне Яһуда ясый һәм туганнарының шуңа ризалашуына ирешә. Бу туганнарның гамәле никадәр гыйбрәтле: иң мәрхәмәтле булганы да көнчелеге аркасында Йосыфны коега ташларга киңәш бирә. Бу исә хөсетлекләре сәбәпле дуслык битлеген кигән күпме яшерен дошманнар барлыгын күрсәтә. Андыйлардан мөмкин кадәр саклану зарур.

Бары сау, тере йөрәк ияләре генә хак юлдан, дөрес юнәлештә бара. Моның капма-каршысы – зикердән ерак йөрәк исә нәфес йогынтысында калыр, шәһвәт утларында кибәр-корыр, катыланыр, ташка әйләнеп, әгъзаларны гыйбадәт кыла алмас бер хәлгә китерер. Шул рәвешле дәвам иткәндә, йөрәкләр коры утын кисәге кебек, утта яндырудан кала, һичбер эшкә ярамас. Мондый хәлгә төшүдән Аллаһ Тәгаләгә сыгыныйк. Җәнабел-Хак болай дип кисәтә:

فَوَيْلٌ لِلْقَاسِيَةِ قُلُوبُهُمْ مِنْ ذِكْرِ اللَّهِ أُولَئِكَ فِي ضَلَالٍ مُبِينٍ

**«...Аллаһның зикеренә (карата йөрәкләре) каты булганнарга ни үкенеч! Алар ап-ачык бер адашу эчендә»** («әз-Зүмәр», 22).

Ахырда Йосыфның ага-энеләре, үзләренең мәкерле планын тормышка ашырыр өчен, аталары янына килә.

قَالُوا يَا أَبَانَا مَا لَكَ لَا تَأْمَنَّا عَلَى يُوسُفَ وَإِنَّا لَهُ لَنَاصِحُونَ.
أَرْسِلْهُ مَعَنَا غَدًا يَرْتَعْ وَيَلْعَبْ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ

**«Әйттеләр: “И, атабыз! Ни өчен син Йосыфны безгә ышанып тапшырмыйсың? Шулай итеп, без – (аны саклаучылар) аңа яхшылык кына теләүчеләрбез. Иртәгә син аны безнең белән бергә (кырга) җибәр: рәхәтләнеп ашасын, эчсен һәм уйнасын. Һичшиксез, без аны саклarбыз”»** («Юсуф», 11–12).

**Бәлаләр авыздан чыккан сүзгә бәйле**

قَالَ إِنِّي لَيَحْزُنُنِي أَنْ تَذْهَبُوا بِهِ وَأَخَافُ أَنْ يَأْكُلَهُ الذِّئْبُ وَأَنْتُمْ عَنْهُ غَافِلُونَ

**«(Аталары) әйтте: “Сезнең аны алып китүегез мине борчуга салыр. Аеруча, мин сез аннан гамьсез калган чакта, аны бүре ботарлап ташлар дип куркам”»** («Юсуф», 13).

Риваятьтә әйтелгәнчә, Хәзрәти Ягъкуб галәйһис-сәләәм бер төш күрә. Төшендә үзе бер тау башында басып тора, улы Йосыф исә сахрада йөри. Кинәт ун бүре килеп чыгып, Йосыфка һөҗүм итә. Йосыф шулар арасында югала. Ягъкуб галәйһис-сәләәм шуңа күрә улларына Йосыф турында: «Аны бүре ашаудан куркам!» – дип, икеләнүен белдерә. Ләкин шул рәвешле, үзе дә сизмәстән, ага-энеләрнең Йосыфка кылачак мәкеренә бәйле бер ысул әйтеп җибәрә, дияргә мөмкин.

Хәдис-шәрифләрдә хәбәр ителә:

*«Бәлаләр авыздан чыккан сүзгә бәйле!»* (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», I, 110).

*«Нәфсем миңа шундый нәрсәләр сөйли ки, аларны сөйләр идем дә, әйткәннәрем белән сыналачакмын дип куркып, сөйләмим...»* (Бурсәви, «Рухул-Бәян», IV, 222).

Кеше дошманнарына үзенә каршы кулланырлык мәсьәләләрдә ысул-җай бирергә, дилбегә тоттырырга тиеш түгел. Йосыфның туганнары ул мизгелгә кадәр мондый план турында уйламаган була. Әтиләре тоттырган җеп очы эләккәч, яшерен план коралар.

Телен кисеп ташланганнан соң үтерелгән Ибне әс-Сиккыйт: «Теле җибәргән ялгышлык аркасында кеше тарыячак авырлыклар аягының хатасы сәбәпле кичерәчәк кыенлыклардан күпкә зуррак була ала! Чөнки кешенең аягы ялгышудан килеп чыккан яра вакыт узу белән төзәлә. Ә авыздан чыккан сүз аркасында кеше хәтта башын югалтырга мөмкин», – дип әйткән.

Ягъкуб галәйһис-сәләәм, күргән төшенә карамастан, гаҗиз хәлдә калып, Йосыфны ага-энеләре кулына тапшыра. Менә бу җөмлә бу халәтне бик төгәл ачып бирә: «Када һәм тәкъдир сәгате җиткәч, күңел күзе, интуиция күрмәс хәлгә калыр!»

«Бу хатаны һич эшләмәм!» – дип әйткән бер бәндә шайтанга ишекне ачык калдыра. Шуннан соң шайтан, бөтен эшен ташлап, аны борчып тора башлый һәм «эшләмәм» дигән нәрсәсен эшләгәнчегә кадәр, бу бәндә янынннан китми (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», I, 110). Бу күзлектән караганда, теге яки бу гамәл турында һичкайчан тулы ышаныч белән әйтмәскә һәм ул гамәл мәсьәләсендә һәрдаим Хак Тәгалә ярдәменә сыгынырга кирәк.

Йосыфның ага-энеләре аталарына һәм туганнарына карата хөрмәтсез мөнәсәбәт күрсәткән була. Шуңа күрә үзләре корган мәкерне тормышка ашыру өчен, этиләренең кисәтүенә колак салган булып, аны күндерергә туры килә:

قَالُوا لَئِنْ أَكَلَهُ الذِّئْبُ وَنَحْنُ عُصْبَةٌ إِنَّا إِذًا لَخَاسِرُونَ

**«Алар әйттеләр: “Әгәр без бер (көчле) җәмәгать була торып, аны бүре ботарлап ташласа, ул тәкъдирдә, һичшиксез, без зыян итүчеләрдән булырбыз (безгә кайгы булсын)”»** («Юсуф», 14).

**Туганнарның хыянәте**

فَلَمَّا ذَهَبُوا بِهِ وَأَجْمَعُوا أَنْ يَجْعَلُوهُ فِي غَيَابَةِ الْجُبِّ
وَأَوْحَيْنَا إِلَيْهِ لَتُنَبِّئَنَّهُمْ بِأَمْرِهِمْ هَذَا وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ

**«Алар аны алып китеп, бер кое төбенә ташларга бердәм карарга килгәч, Без исә аңа (Йосыфка) вәхи иттек: “(Вакыты киләчәк), син аларның уйларында да булмаганда, аларга бу эшләрен хәтерләтәчәксең”»** («Юсуф», 15).

Аятьтәге **«Без исә Йосыфка вәхи иттек»** гыйбарәсенә нигезләнеп, күп кенә мөфәссирләр Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәмгә ул вакытта ук пәйгамбәрлек йөкләнгән була, дип аңлата.[99]

Улларының энеләре Йосыфны сахрага алып чыгарга теләп үҗәтләнүенә һәм Йосыфның да алар белән барасы килүенә бирешеп, Ягъкуб галәйһис-сәләәм язмышка буйсына да бу эшкә ризалык бирә. Ага-энеләр, этиләренең күңеле тынычлансын өчен, ул тәмам күздән югалганчы, Йосыфны иңбашларына күтәреп баралар. Әтиләре инде күренми башлауга, биргән сүзләреннән баш

99. Аллаһ Тәгалә Яхъя һәм Гайсә галәйһимәс-сәләмнәргә вәхине балигъылык чорыннан башлап җибәрә. Шул рәвешле кайбер колларын Ул, алдан әзерләп, Үзе теләгән вакытта аларга пәйгамбәрлек ишекләрен ача. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү кайбер колларына исә кечерәк яшендә үк әүлиялык ишеген ачып җибәрә. Әүлиялардан Сәһл ибне Габдуллаһ әл-Түстәри әнә шундыйлар исәбендә. Бу исә әүлиялык һәм пәйгамбәрлек өчен балигъылык чорына яки кырык яшькә җитү шарт түгеллеген күрсәтә. Ләкин пәйгамбәрләрнең күпчелегенә Аллаһ сөннәте кушканча камил чор булган кырык яшьтән соң гына пәйгамбәрлек бирелә. Шул рәвешле дәгъват вазифасы, гомумән алганда, кырык яшьтән соң гына башланган.

тарталар. Алар Йосыфны ачу белән җиргә ташлый һәм: «Әй, ялганчы төшләр уйлап чыгаручы! Үзеңә сәҗдә кылганнарын күргән йолдызлар кайда? Менә килеп хәзер сине безнең кулдан коткарсыннар!» – диләр. Шуннан соң Йосыф галәйһис-сәләамне кыйный һәм мыскыллый башлыйлар. Йосыф кайсы туганына ярдәм сорап ялварса, шуның тарафыннан тагын да ныграк кыйнала, изелә, җәзалана. Бу хәлдән ул, бичара калып, елый башлый. «И, эткәм! Синә биргән сүзләрен һәм син аларга биргән нәсыйхәтне шундый тиз оныттылар! Аларның нишләгәннәрен күрсәңме, улыңа кылынган җәфа-газапларны хәтта колның баласына карата да кылмаслар!» – ди ул.

Риваятькә күрә, Робил Йосыфны күтәреп алып, җиргә ора. Аннары тиз генә күкрәгенә утырып, аны үтерергә маташа. Икенче туганы Ләви исә муенын сындырырга тели. Йосыф кардәшләренең иң мәрхәмәтлесе булган Яһудага: «И, Яһуда! Аллаһтан курык һәм мине үтерергә теләүчеләргә каршы бул!» – дип ялвара. Яһудада мәрхәмәт хисе уянып, ул: «Аны үтермәгез! Бу хакта миңа сүз бирмәдегезме?» – ди. Ага-энеләр: «Әйе, бирдек!» – диләр. Шуннан соң Яһуда: «Үтерүгә караганда хәерлерәкне әйтимме сезгә? Аны коега ташлагыз!» – дип тәкъдим итә.

### Хәзрәти Йосыфның коега ыргытылуы

Башкалар да Яһуданың тәкъдимен «бик әйбәт!» дип хуплагач, берталыштан Йосыфны коега ыргытырга килешәләр.

Бу кое Иордания тирәсендә була. Аны Гад кавеменең залим хөкемдарларыннан Шәддад Иорданияне төзегән чакта казыта. Коеның авызы тар, төбе киң итеп ясала.

Ага-энеләр кое авызы янына килә. Йосыф туганнарының киемнәренә ябыша-ябыша елый, ләкин абыйлары аны кага гына. Йосыфны коеның яртысына кадәр асып төшерәләр. Бер җиргә дә тотына алмасын, дип, кулларын бәйлиләр, күлмәген салдыралар. Ага-энеләр аталары алдында аклану, аны ышандыру өчен, бер сарык суеп, шуның канын күлмәккә буярга карар кылалар.

Күлмәген салдырган туганнарына Йосыф: «И, кардәшләрем! Күлмәгемне бирегез; үлсәм, миңа кәфен булыр, исән калсам, киемем булыр!» – дисә дә, күлмәкне кире кайтармыйлар.

Йосыфны коеның яртысына кадәр асып төшергәннән соң, егылып төшеп үлсен, дип, бауны кисәләр. Коеда су була. Йосыф кое читендәге бер таш өстенә ябыша да, аягына баскач, бәлки, туганнарымда мәрхәмәт уянып, үзен аннан чыгарырлар, дигән өмет белән югарыга дәшә. Әмма ага-энеләре: «Үлмәгән икән!» – дип, аның өстенә таш яудырырга тели. Янә Яһуда каршы килә.

Туганнары Йосыфны коега асып төшергәндә, Аллаһ Тәгалә Җәбраилгә мөрәҗәгать итә: «Колыма ярдәмгә өлгер!»

Җәбраил галәйһис-сәләәм, боерыкны шундук үтәп, Йосыфны тотып ала да, коедагы бер таш өстенә утырта. Аңа җәннәт ризыкларын ашата-эчертә. Аннары Ибраһим галәйһис-сәләәмнең күлмәген кидерә.

Хәсән Басри куддисә сирруһ: «Коега ыргытылганда, Йосыф унике яшьтә була. Атасы Ягъкуб аның белән кырык елдан соң кавыша», – дип әйткән.

Кое бик куркыныч була, эчендә еланнар, чаяннар һәм башка хәшәрәтләр яши. Аларның барсына да бу җирдән чыгып китәргә кушыла.

Йосыф галәйһис-сәләәм, коега ыргытылгач, Аллаһ Тәгаләгә болай дип ялвара: «И, яшерен булмаган шаһит! И, ерак булмаган якын зат! И, һич җиңелмәгән җиңүче! Үзем эләккән авыр хәлдән мине ирекккә чыгар! Миңа бер котылу ишеген ач!»

Риваятькә күрә, Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм коеда өч көн ята. Бер сәгать кенә калганлыгы турында да риваять бар.

Җәбраил галәйһис-сәләәм коеда Йосыфка менә бу доганы өйрәтә: «И, һәртөрле кыенлыкларны бетерүче! И, һәр догага җавап бирүче! И, һәртөрле сынган урыннарны бәйләүче! И, һәртөрле авырлыкны җиңеләйтүче! И һәр ятимнең хуҗасы һәм һәр ялгызның сөеклесе булган Аллаһым! И, аннан башка илаһ булмаган Раббым! Синең һәр кердән пакь икәнлегеңне таныйм! Үзем тарыган бу кыенлыктан бер ирек, яктылык, бу бәладән котылу ишеген ачуыңны Синнән сорыйм! И, Аллаһым, мәхәббәтеңне йөрәгемә шундый итеп урнаштыр ки, моннан соң һичбер кайгым калмасын, анда Синнән башка зат зикер ителмәсен. И, Раббым, мине якла! Йә Әрхәмәр-Рахимин!»

Йосыф галәйһис-сәләәм коега ыргытылгач, Аллаһны зикер кыла башлый. Фәрештәләр аның тавышын ишеткәч, Аллаһ Тәгаләдән бу матур тавышны тыңлар өчен рөхсәт сорыйлар. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү дә фәрештәләргә болай дип әйтә:

«Сез элегрәк:

أَتَجْعَلُ فِيهَا مَنْ يُفْسِدُ فِيهَا وَيَسْفِكُ الدِّمَاءَ وَنَحْنُ نُسَبِّحُ بِحَمْدِكَ وَنُقَدِّسُ لَكَ

**«…(Йә Раббы!) “Әллә җирдә бозыклык кылучыны һәм кан коючыны яралтачаксыңмы? Без бит һәрвакыт Сиңа мактау белән тәсбих әйтәбез, олылыйбыз”, – димәгән идегезме?»** («әл-Бәкара», 30). Фәрештәләрнең әүвәлрәк әйткәннәрен искә төшергәч, соңыннан аларга рөхсәт бирә.

Җан һәм йөрәк рухи галәмгә омтылыр. Нәфескә караган физик куәт һәм хисләр хайвани галәмгә йөз тотар. Әгәр кеше үз көенә калдырылса, нәфес җиңү яулар, ул җан өстеннән хөкем кыла башлый. Бу – хак юлдан тайпылганнар халәте.

Әгәр йөрәк зикер һәм гамьле әңгәмәләр белән күркәм әхлакка лаек булса, җиңү җан һәм рух тарафына күчә. Нәфес һәм бәдән җан белән йөрәк биргән юнәлешкә буйсыныр. Бу исә – изге бәндәләрнең халәте.

Пәйгамбәрләр һәм әүлиялар Аллаһ тарафыннан вәхи һәм илһам белән ныгытылганга күрә, башларына төшкән бәла-казаларга сабыр-түземлек күрсәтә, мондый сынауларны йөрәкләренең Җәнабел-Хакка якынаюына бер сәбәпкә әйләндерерләр.

Бөтен авырту-җәфаларына карамастан, сабыр итсеннәр һәм Аллаһка бәйлелекләре тагын да артып, һәрвакыт Хак Тәгаләгә йөз тотсыннар, дип, Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Ягъкуб һәм Йосыф галәйһимәс-сәләмнәргә берсеннән-берсе авыр иза-газаплы, кайгы-хәсрәтле язмыш билгели. Һәрдаим Аның белән бергә булсыннар һәм бөтен фани бәйләнеш-мөнәсәбәтләрдән арынып, югары дәрәҗәгә ирешсеннәр өчен! Чөнки кайбер шундый бөек мәртәбәләргә бары михнәт-кыенлыкларга түзү аша гына ирешергә мөмкин.

Димәк, Хәзрәти Йосыфның унике ел төрмәдә калуының бер хикмәте аның ялгызлык, ачлык, кыенлыклар һәм Аллаһ юлында көрәш аркылы рухи камиллеккә ирешүендә яшеренгән. Йосыф атасы янында калган очракта, бәлки, аңа бәйле мондый вакыйгаларның чынга ашуы насыйп кылынмас иде. Әнә шул хикмәт сәбәпле пәйгамбәрләр, билгеле бер вакыт аралыгында үз ватаннарыннан читтә яшәргә мәҗбүр ителгән.

Йосыфны коега аткан туганнары, өйгә кайткач, елаган булып кыланып, әтиләре янына киләләр. Аяти кәримәләрдә әлеге күренеш түбәндәгечә тасвирлана:

وَجَاؤُوا أَبَاهُمْ عِشَاءً يَبْكُونَ. قَالُوا يَا أَبَانَا إِنَّا ذَهَبْنَا نَسْتَبِقُ وَتَرَكْنَا يُوسُفَ عِنْدَ مَتَاعِنَا فَأَكَلَهُ الذِّئْبُ وَمَا أَنْتَ بِمُؤْمِنٍ لَنَا وَلَوْ كُنَّا صَادِقِينَ

**«Алар кичен елый-елый аталарына килделәр. Әйттеләр: “И, атабыз! Без чыктык, ярыша идек. Йосыфны исә әйберләребез янында калдырган идек, (бер кайтуыбызга) аны бүре ашаган. Без дөрес сүзле кешеләр булсак та, син безгә берничек тә ышанмассың инде!”»** («Юсуф», 16–17).

Риваятькә карасак, ире белән ачуланышкан бер хатын, елый-елый, казый Шурайхка мөрәҗәгать итә. Бу вакытта анда булган Шагъби казыйга: «Йә Әба Өмәййә! Бу хатын золым корбаны булган, дип уйлыйм. Ничек елаганын күрмисеңмени?!» – ди. Шуннан соң казый Шурайх: «Әй, Шагъби! Йосыфның туганнары да, залим булуга карамастан, аталары янына елап килгәннәр. Андый елау-сыктауларга карап хөкем чыгару – дөрес булмас! Килеп чыккан вакыйганың асылына карап кына хөкем йөртү кирәк», – дип аңлата.

Йосыфның туганнары, ялган күз яшьләре агызу гына түгел, моңа өстәп:

وَجَآؤُوا عَلَى قَمِيصِهِ بِدَمٍ كَذِبٍ قَالَ بَلْ سَوَّلَتْ لَكُمْ أَنْفُسُكُمْ
أَمْرًا فَصَبْرٌ جَمِيلٌ وَاللّٰهُ الْمُسْتَعَانُ عَلَى مَا تَصِفُونَ

**«Алар аның (Йосыфның) күлмәгенә ялган бер кан алып килделәр. (Аталары Ягъкуб) әйтте: "Нәфесләрегез сезгә күрелмәгән бер эшне бизәп күрсәткән. (Миңа, өметне югалтмыйча,) күркәм сабырлык (күрсәтергә генә кала). Сезнең сөйләгәннәрегезгә каршы Аллаһтан гына ярдәм сорарга кирәк"»** («Юсуф», 18).

Риваятькә күрә, Йосыфның каны буялган күлмәкне Ягъкуб галәйһис-сәләамгә алып килгәч, ул күлмәкне йөзенә каплап елый башлый һәм: «Бу көнгә кадәр мондый йомшак холыклы бер бүре дә күрмәдем! Улымны ашаган, тик сыртындагы күлмәген ертмаган!» – ди.

**Иң матур сабырлык**

Ягъкуб галәйһис-сәләам улы Йосыф өчен күңелдән кайгыруы, эчтән генә елавы телдән-телгә күчеп, гасырлар буе макталган. Моны шагыйрь Юныс Әмрә түбәндәгечә сурәтли:

«Мәүланың исеме бар иде телемдә,
Югалттым Йосыфны Кәнан илендә.
Елый да елый Ягъкуб: "Йосыфым", – дия-дия!
"Йосыфымны алып китеп, кан иттеләр,
Бүреләр ашады, дип яла әйттеләр.
Йосыфның күлмәген, белмим, нишләттеләр".
Елый да елый Ягъкуб: "Йосыфым", – дия-дия!»

Әнә шулай күз яше түккән Ягъкуб галәйһис-сәләамгә инде сабыр итүдән башка чара калмый. Чыннан да, ул һичкемгә зарланмыйча, үз хәленә сабыр итә һәм:

قَالَ إِنَّمَا أَشْكُوا بَثِّي وَحُزْنِي إِلَى اللّٰهِ

**«"Мин хәсрәтемне һәм борчуымны Аллаһка гына шикаять итәм", – диде…»** («Юсуф», 86).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез Җәбраил галәйһис-сәләамнән: *«Ягъкубның Йосыфны сагынып кайгыруы нинди дәрәҗәгә җиткән иде?»* – дип сорый. Җәбраил галәйһис-сәләам: «Баласын югалткан җитмеш ананың барысының бергә сагыш-кайгысы кадәр дәрәҗәгә!» – дип җавап бирә.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез: *«Ул очракта моның савабы никадәр?»* – дигән сорау бирә. «Йөз шәһидлек савабы, чөнки ул Аллаһ турында бер мизгелгә генә дә начар уйлап карамады», – дип белдерә Җәбраил галәйһис-сәләәм (Суюти, «әл-Дуррүл-Мәнсур», IV, 570). Әнә шундый сабырлык «иң матур сабырлык» була да инде.

Иң матур сабырлык – башка төшкән бәла-казаларны, бәндәләргә һичкайчан, һичтөрле зарланмыйча, кычкырып еламыйча, түземлек һәм язмышка буйсынучанлык белән кичерү дигән сүз. Әгәр авырлыкка тарыган кеше Аллаһның башка бәндәләренә зарланса, бу аңарда мондый сабырлык сыйфаты юкка чыгуын белдерә.

**Хәзрәти Йосыфның коедан чыгарылып, сатып җибәрелүе**

Атасы иң матур сабырлык үрнәге күрсәткәндә, Хәзрәти Йосыф та коеда шундый ук буйсынучанлыгын, Аллаһка гына бирелгәнлеген раслый. Шул вакыт мондый хәл була:

وَجَاءَتْ سَيَّارَةٌ فَأَرْسَلُوا وَارِدَهُمْ فَأَدْلَى دَلْوَهُ قَالَ يَا بُشْرَى هَذَا غُلَامٌ وَأَسَرُّوهُ بِضَاعَةً وَاللَّهُ عَلِيمٌ بِمَا يَعْمَلُونَ. وَشَرَوْهُ بِثَمَنٍ بَخْسٍ دَرَاهِمَ مَعْدُودَةٍ وَكَانُوا فِيهِ مِنَ الزَّاهِدِينَ

**«Бер кәрван килгәч, сучыларны (коега) җибәрделәр. Ул чиләген төшереп җибәрде (Йосыфны күргәч): “Әй, сөенечем! Бу бит – бер ир бала!” – диде. Аны (сатулык мал итеп сату нияте белән) маллары арасына яшерделәр. Аллаһ исә аларның ни кылганнарын күрүче иде. (Ниһаять, Мисырга килгәч), алар аны аз бер бәягә – берничә дирһәмгә генә сатып җибәрделәр һәм аның өчен зур бәя сорамадылар»** («Юсуф», 19–20).

Йосыфны сатучылар, чибәрлегеннән күзләре камашуга карамастан, аны очсыз хакка сатып җибәрә. Хуҗасы килеп чыгар да бездән Йосыфны бирүебезне таләп итәр, дип, курка-курка, чибәрлегенә сокланып тормыйча, аны тизрәк кулдан ычкындыру җаен карыйлар.

Шәех Әкбәр Мухйиддин Ибне Гарәби куддисә сирруһ болай дигән:

«Җәнабел-Хак:

وَكَانَ أَمْرُ اللَّهِ قَدَرًا مَقْدُورًا

**«”...Аллаһның әмере – тәкъдир ителгән бер хөкем!”»** – дигән серенең («әл-Әхзәб», 38) чынга ашуын максат итеп куйгач, моны колларына берәр ялгышлык эшләттереп башкарыр».

Йосыф галәйһис-сәләәм дә беркөнне көзгедә үз сурәтен күреп, матурлыгына сокланган һәм: «Әгәр кол итеп сатылсаммы, миңа бәя бирелә алмас иде,

бик кыйбат торыр идем!» – дип әйткән була. Үз-үзенә сокланып кылган хатасы сәбәпле, аны кол итеп, өстәвенә, бөтенләй арзан бәягә саталар.

Мондый риваять кылына:

Беркөнне Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәчеттән үз йортына кайтканда, бер төркем бала-чага Аның юлына каршы чыга: «Хәсән белән Хөсәенгә биргән кебек, безгә дә берәр нәрсә бирмәсәң, Сине җибәрмибез!» – диләр.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Билал радыйаллаһу ганһегә: *«Өйгә кер дә ни тапсаң, шуны алып кил. Үземне болардан сатып алыйм!»* – ди.

Билал китеп, сигез чикләвек алып килә. Рәсүлүллаһ шул чикләвек бәрабәренә үзен балалардан сатып ала. Аннары: *«Туганым Йосыфны очсыз бәягә сатканнар. Менә мине дә сигез чикләвеккә саттылар!»* – дип, йомшак кына шаяртып куя.[100]

Тышкы яки фани матурлык түгел, ә күңел, әхлак матурлыгы мөһим. Бу үзенчәлек хәдис-шәрифтә түбәндәгечә белдерелә:

*«Аллаһ Тәгалә сезнең бәдәннәрегезгә һәм сурәтләрегезгә түгел, йөрәкләрегезгә карар»* (Мөслим, «Бирр», 33; Ибне Мәҗә, «Зүһд», 9).

Әйтик, Һаҗәр анабыз Фиргавен тарафыннан Сара анабызга җария итеп бирелә. Һаҗәр анабыздан Исмәгыйль галәйһис-сәләам, аның нәселеннән исә Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез дөньяга килә.

Бәдән төзелешенең әллә ни кыйммәте юк. Ул җанның тышлыгы ролен башкара. Кеше рухи төзелеше белән гыйззәт һәм хөрмәт казана яисә оятка кала. Ягъни бер кешенең саф йөрәге һәм күркәм гамәлләре бар икән, Аллаһ катында кабул булыр. Ә аның матур йөз-кыяфәте яки бик күп мал-мөлкәте булу-булмау – әһәмиятле түгел.

Кешенең бәдәне, колга әйләнгәч, никадәр очсыз хакка сатыла! Җанын-күңелен шәһвәт һәм нәфес теләкләренең колына әйләндергәннәр нинди язмышка дучар булачаклар?! Димәк, мөэмин үзенең кыйммәтен һәм гыйззәтен белергә, ул һичкайчан нәфесенә коллыкка төшмәскә тиеш. Җәнабел-Хак болай ди:

أَرَأَيْتَ مَنِ اتَّخَذَ إِلٰهَهُ هَوَاهُ أَفَأَنْتَ تَكُونُ عَلَيْهِ وَكِيلًا

**«(Рәсүлем!) Яман теләген (нәфес теләкләрен) үз илаһы иткән кешене күрдеңме? Әллә аңа син Яклаучы буласыңмы? (Ягъни аңа яклаучы булып та, аны коткара алмассың!)»** («әл-Фуркан», 43).

Аяти кәримәдә әйтелә:

100. Карагыз: Бурсәви, «Рухул-Бәян», «Юсуф» сүрәсе, 20 нче аятьнең тәфсире.

وَقَالَ الَّذِي اشْتَرِيهُ مِنْ مِصْرَ لِامْرَأَتِهِ أَكْرِمِي مَثْوِيهُ عَسَى أَنْ يَنْفَعَنَا
أَوْ نَتَّخِذَهُ وَلَدًا وَكَذٰلِكَ مَكَّنَّا لِيُوسُفَ فِي الْأَرْضِ وَلِنُعَلِّمَهُ مِنْ تَأْوِيلِ
الْأَحَادِيثِ وَاللّٰهُ غَالِبٌ عَلَى أَمْرِهِ وَلٰكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ

**«Мисырдан аны (Йосыфны) сатып алган кеше хатынына: “Аның яшәр урынын яхшы кара. Бәлки, безгә файдалы булыр яки аны үзебезгә бала итәрбез”, – диде. Без шулай Йосыфка ул туфракта урын бирдек. Без аңа вакыйгаларның тәгъбирен өйрәтик дип. Аллаһ әмерләрен җиңү белән тәгәлли, ләкин кешеләрнең күбесе белмиләр»** («Юсуф», 21).

Тәфсирләрдән аңлашылганча, Йосыф галәйһис-сәләәмне сатып алган кол сатучы соңыннан аны Мисырның финанслар министрына сатып җибәрә. Чөнки финанслар министры Хәзрәти Йосыфның зирәклеген һәм сәләтен сизә, шуңа күрә киләчәктә аны дәүләт эшләрендә куллана алачагын уйлый. Шулай ук үз баласы булмаганга күрә, Йосыфны уллыкка алу теләген дә күз уңында тота.

Газизнең Йосыфны сатып алуы кол итеп арзан хакка сатылганнан соң, кыйбат бәягә дә сатыла алуына ишарәли. Йосыфны беренче булып сатып алган сәүдәгәр аны бизәп сатуга чыгаргач, аукцион өч көн бара. Ахыр чиктә Йосыфны, аның авырлыгы кадәр мускус, шулкадәр үк энҗе, шулкадәр үк алтын, шулкадәр үк көмеш һәм ефәк бәрабәренә мисырлы Газиз сатып ала.

Кайбер риваятьләрдә Аллаһ Тәгаләнең болай дип әйткәне тапшырыла: «Әй, Адәм баласы! Син бер нәрсә ниятләрсең, Мин исә башка максат куярмын. Һәм бары Минем ниятләгәнем генә чынга ашар. Әгәр син Минем максатыма буйсынсаң, синең максатыңны үзеңә бирермен. Әгәр ният-максатым турында Минем белән тартыша башласаң, синең максатыңны пыран-заран китерермен. Нәтиҗәдә янә Минем максатым чынга ашкан булыр...»

Коръәни-Кәримдә Аллаһ Тәгалә гыйлемне мактый, наданлыкны яманлый.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән: «Йә, Рәсүлүллаһ! Гамәлләрнең кайсысы фазыйләтлерәк?» – дип сорыйлар. Ул: *«Аллаһны тану!»* – дип җавап бирә. «Кайсы гамәл дәрәҗәне күтәрер?» – дип сорагач, янә: *«Аллаһны тану!»* – дигән җавап яңгырый. Шуннан соң: «Йә, Рәсүлүллаһ! Без гамәл турында сорыйбыз. Сез гыйлем турында җавап бирәсез!» – дип әйткәч, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Мәгърифәтуллаһ (Аллаһны танып-белү) белән кылынган аз гамәл дә файда китерер. Ләкин җаһиллек белән кылынган күп гамәл дә файдасыз булыр!»* – дип белдерә (Мүнави, «Фәйзүлкадир», IV, 688).

Күренекле кешеләр әйткәнчә, гыйлемдә камиллеккә ирешү гамәлдә камиллеккә җитүдән фазыйләтлерәк. Фәкать гыйлемдә бер ялгышлык та

гамәлдә хата җибәрүдән куркынычрак. Чөнки саф гакыйдә гамәлнең беренчел шарты булып тора. Шунлыктан Пәйгамбәрләр, гыйлемнәрен арттырсын өчен, Җәнабел-Хакка дога кылганнар. Адәм галәйһис-сәләам фәрештәләрнең хөрмәтенә һәм сәҗдә кылуына – үзенә бирелгән исемнәр бәрабәренә; Сөләйман галәйһис-сәләам үзенең бөек солтанлыгына – аңа насыйп ителгән нәфис аң-зиһен, идарә осталыгы белән; Йосыф галәйһис-сәләам авыр зинданнардан котылуга һәм солтанлыкка исә тәгъбир гыйлемен белүе сәбәпле лаек була.

**Хәзрәти Йосыф һәм Зөләйха**

Коръәни-Кәримдә Аллаһ Тәгалә болай дип әйтә:

وَلَمَّا بَلَغَ أَشُدَّهُ آتَيْنَاهُ حُكْمًا وَعِلْمًا وَكَذَلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ

**«Ул җитлегү яшенә җиткәч, Без аңа хөкем һәм гыйлем бирдек. Без игелек ияләренә шулай әҗерләрен бирәбез»** («Юсуф», 22).

Хәзрәти Йосыф үсә, өлгерә һәм чибәр килеш-кыяфәтле егет булып җитешә. Аның матурлыгы ул яшәгән йортның хуҗабикәсе Зөләйхада Йосыфка карата төрле уй-ниятләр барлыкка килүенә сәбәп була. Бу вакыйга аяти кәримәдә түбәндәгечә искә алына:

وَرَاوَدَتْهُ الَّتِي هُوَ فِي بَيْتِهَا عَنْ نَفْسِهِ وَغَلَّقَتِ الْأَبْوَابَ وَقَالَتْ هَيْتَ لَكَ قَالَ مَعَاذَ اللَّهِ إِنَّهُ رَبِّي أَحْسَنَ مَثْوَايَ إِنَّهُ لَا يُفْلِحُ الظَّالِمُونَ. وَلَقَدْ هَمَّتْ بِهِ وَهَمَّ بِهَا لَوْلَا أَنْ رَأَى بُرْهَانَ رَبِّهِ كَذَلِكَ لِنَصْرِفَ عَنْهُ السُّوءَ وَالْفَحْشَاءَ إِنَّهُ مِنْ عِبَادِنَا الْمُخْلَصِينَ

**«Хатын (Йосыфны үзенә бәйләү, аның нәфесен кузгату нияте белән) хәйләгә барды ки, ул (Йосыф) исә аның өендә яши иде. Ул ишекләрне бикләде һәм: “Бире кил!” – диде. Ул исә: “Аллаһ сакласын! (Аллаһка сыгынырмын!) Минем әфәндем (миңа карата яхшы мөгамәлә күрсәтте) каласы урынымны яхшы кылды. Һичшиксез, залимнәр уңышка ирешмәячәк”, – диде. Ул хатын аны теләде. Раббысыннан борһан (дәлил һәм ярдәм) күрмәгән булса, (Йосыф та) аңа омтылыр иде. Без яманлык һәм фахишәтне аңардан шулай бордык. Һичшиксез, ул – Безнең ихлас колларыбыздан иде»** («Юсуф», 23–24).

Зөләйхада нәфесләрнең иң зәгыйфь өч үзенчәлеге, ягъни байлык, даншөһрәт һәм шәһвәтнең иң югары дәрәҗәсе бергә туплана. Ул – яшь, чибәр йөзле һәм бик күпләрне үзенә җәлеп итә алырлык мөлаемлык сыйфатларына ия хатын була. Өстәвенә Зөләйха бүлмәнең ишеген дә бик яхшылап бикләп куя. Шул рәвешле яшеренлек һәм аулак урын гөнаһ эшләргә тагын да ныграк котырткан вакытта, ул Хәзрәти Йосыфка бик көчле теләк белән: «Һәйтә ләк!», ягъни «Бире кил!» дип дәшеп, әшәке гамәлен тормышка ашырырга керешә.

Нинди куәтле ихтыяр көченең дә түземлелек сәләтен эретерлек мондый манзара каршында Йосыф галәйһис-сәләамнең дә шактый авыр хәлдә калуын Бөек Раббыбыз: «Әгәр борһаныбыз күрмәгән булса, ул да аңа омтылыр иде», – дигән сүзләр белән белдерә. Чөнки ир-ат өчен ул үз гомерендә кичерергә мөмкин иң авыр сынау – яшьлек, чибәрлек, дәрәҗә кебек җәлеп итү сыйфатларына ия хатын-кыз тарафыннан (бигрәк тә, аулакта) нәфсани чакыруга, игътибарга «юк» дип җавап бирә алу.

Менә Йосыф галәйһис-сәләам дә, алдына сибелгән куәтле кызыктыргыч нәрсәләргә (чибәр хатын, аның байлыгы, дәрәҗәсе) алданмас өчен, «мәгазаллаһ» дип, рухи көбә бөркәнә, тулы ихласлык һәм бик зур тәкъвалык хисе белән «Аллаһка сыгына». Шулай итеп Йосыф галәйһис-сәләам аяти кәримәдә белдерелгән «борһан» ярдәмендә илаһи яклау һәм саклауга лаек була.

Шуңа күрә дөньялыкта гөнаһларга этә-тарта торган барлык ымсындыргыч нәрсәләрнең «Һәйтә ләк!», ягъни «Бире кил!» дип яңгыраган чакыруларына каршы адәм балалары өчен түземлек күрсәтүнең бердәнбер юлы шул мизгелдә күңелдән «мәгазаллаһ» дип, чиксез кодрәт иясе Аллаһка сыгына белүдән гыйбарәт.

Кайбер тәфсирләрдә аяти кәримәдәге «борһан» сүзе белән бәйле рәвештә түбәндәге аңлатмалар бирелә:

Йосыф галәйһис-сәләам: «Сак бул, тыел!» – дигән тавыш ишеткәч, моңа игътибар бирми. Ләкин ул тавыш өч тапкыр кабатланганнан соң, ул урында атасы Хәзрәти Ягъкуб галәйһис-сәләам күз алдына килә. Бу мәлдә Йосыф галәйһис-сәләам, аңына килеп, Зөләйхадан шундук йөз чөерә. Аллаһның рөхсәте белән Ягъкуб галәйһис-сәләам улы Йосыфка рухи ярдәм күрсәтә, нәфесне котыртучы булган Зөләйхага тартылуына комачаулый.

Аятьтә тасвирланган бу вакыйга дога аша булышу (истиганә), рухи ярдәм (истигазә) һәм күңел белән Аллаһка багланышка (рабыта) үрнәк булып тора.

Гали ибне Хәсән бер риваятьтә болай бәян кыла:

Зөләйха әзерләгән бүлмәдә бер пот була. Йосыфны үзенә каратырга, ымсындырырга чакырганчы, бу потны бер җәймә белән каплый. Моны күргәч, Йосыф: «Ник болай эшләдең?» – дип сорый. Зөләйха: «Мине бәхетсез хәлдә күрүеннән оялдым!» – дип җавап бирә. Шуннан соң Йосыф әйтә: «Син ишетмәгән, күрмәгән һәм бернәрсә дә аңламаган бер таш кисәгеннән ояласың да, мине яралткан һәм дә иң күркәм сурәттә яралткан Раббымнан минем оялырга хакым юкмы?»

Йосыф галәйһис-сәләам Раббысының борһанын күргәч, бик куркуга калып, тиз-тиз ишеккә йөгерә. Зөләйха дә аның артыннан бара:

وَاسْتَبَقَا الْبَابَ وَقَدَّتْ قَمِيصَهُ مِنْ دُبُرٍ وَأَلْفَيَا سَيِّدَهَا لَدَى الْبَابِ قَالَتْ مَا جَزَاءُ مَنْ أَرَادَ بِأَهْلِكَ سُوءًا إِلَّا أَنْ يُسْجَنَ أَوْ عَذَابٌ أَلِيمٌ

**«Икесе дә узышып ишеккә ташландылар. Ул (хатын) аның күлмәген арткы яктан ертты. Ишек янында аның (хатынның) ирен очраттылар. Ул хатын (шундук): «”Синең гаиләңә бер яманлык теләгән кешенең җәзасы зинданга ябылудан яки тилмерткеч бер газаптан башка нәрсә була ала?” – диде»** («Юсуф», 25).

Газиз: «Минем гаилә кешесенә кем яманлык эшләргә теләде?» – дип сорый. Зөләйха кылган хатасына тагын берне өсти: ул, Хәзрәти Йосыфка яла ягып: «Бу егет мине аздырырга маташты», – ди. Газиз, Йосыфка таба борылып: «Әй, егет! Сиңа эшләгән яхшылыгыма каршы шушымы күрәчәгем?! Мине борчырга, кайгыга салырга тиеш түгел идең!» – дип әйтә.

Йосыф галәйһис-сәләам вакыйга барышында яла зәхмәтеннән саклану өчен, чынбарлыкны аңлатырга тырыша:

قَالَ هِيَ رَاوَدَتْنِي عَنْ نَفْسِي وَشَهِدَ شَاهِدٌ مِنْ أَهْلِهَا إِنْ كَانَ قَمِيصُهُ قُدَّ مِنْ قُبُلٍ فَصَدَقَتْ وَهُوَ مِنَ الكَاذِبِينَ. وَإِنْ كَانَ قَمِيصُهُ قُدَّ مِنْ دُبُرٍ فَكَذَبَتْ وَهُوَ مِنَ الصَّادِقِينَ

**«Ул: “Ул мине аздырырга теләде”, – диде. Шулчак гаиләсеннән бер шаһит шаһитлык итте: “Әгәр аның (Йосыфның) күлмәге алдан ертылган булса, хатын дөресен әйтә. Ул (Йосыф) исә – ялганчылардан. Әмма әгәр аның күлмәге арттан ертылган булса, хатын ялган сөйләгән, ул (Йосыф) исә – дөресләрдән”»** («Юсуф», 26–27).

Үзенең пакьлеген раслый торган берәр дәлил күрсәтсен өчен, Йосыф галәйһис-сәләам Аллаһка дога кыла. Шулвакытта Зөләйханың агасының өч-дүрт айлык улы, могҗиза булып, сөйләшә башлый һәм Йосыфның сафлыгына шаһитлык кыла.[101]

فَلَمَّا رَأَى قَمِيصَهُ قُدَّ مِنْ دُبُرٍ قَالَ إِنَّهُ مِنْ كَيْدِكُنَّ إِنَّ كَيْدَكُنَّ عَظِيمٌ. يُوسُفُ أَعْرِضْ عَنْ هَذَا وَاسْتَغْفِرِي لِذَنْبِكِ إِنَّكِ كُنْتِ مِنَ الْخَاطِئِينَ.

**«Ул (Газиз) аның (Йосыфның) күлмәген арттан ертылган килеш күргәч, (хатынына) әйтте: “Һичшиксез, бу – сезнең (хатын-кызларның) хәйләләрегездән берсе. Һичшиксез, сезнең хәйләгез бик зур. И, Йосыф! Моннан (вакыйганы читләргә сөйләүдән) йөз чөер. (И, хатын!) Син исә**

101. Тәбәри, Мөхәммәд ибне Җәрир, «Җәмигул-Бәян ан Тәэвили Айил-Куръан», I–XXIV, Әхмәд Мөхәммәд Шакир, «Мүәссәсәтүр-Рисалә», 1420/2000, XVI, 59.

**гөнаһың өчен ярлыкау сора. Һичшиксез, син гөнаһ кылучылардан булдың"»** («Юсуф», 28–29).

Әлеге вакыйга турында халыкка сүз чыга.

وَقَالَ نِسْوَةٌ فِي الْمَدِينَةِ امْرَأَةُ الْعَزِيزِ تُرَاوِدُ فَتَيهَا عَنْ نَفْسِهِ
قَدْ شَغَفَهَا حُبًّا إِنَّا لَنَرِيهَا فِي ضَلَالٍ مُبِينٍ

**«Шәһәрдәге (кайбер) хатыннар әйттеләр: "Хатын (Газизнең хатыны) егетне аздырырга маташкан. Һичшиксез, ул (Йосыф) гыйшык белән аның йөрәк пәрдәсен ерткан. Без аны ап-ачык адашу эчендә күрәбез"»** («Юсуф», 30).

**Йосыфны күргән хатыннар кулын кисә**

Үзе турындагы имеш-мимешләрне ишеткән Зөләйха Мисыр хатыннарын сынарга карар кыла:

فَلَمَّا سَمِعَتْ بِمَكْرِهِنَّ أَرْسَلَتْ إِلَيْهِنَّ وَأَعْتَدَتْ لَهُنَّ مُتَّكَأً
وَآتَتْ كُلَّ وَاحِدَةٍ مِنْهُنَّ سِكِّينًا وَقَالَتِ اخْرُجْ عَلَيْهِنَّ فَلَمَّا رَأَيْنَهُ أَكْبَرْنَهُ وَقَطَّعْنَ
أَيْدِيَهُنَّ وَقُلْنَ حَاشَ لِلَّهِ مَا هَذَا بَشَرًا إِنْ هَذَا إِلَّا مَلَكٌ كَرِيمٌ

**«Ул (хатын) аларның хәйләләрен ишеткәч, аларга (чакыру) җибәрде дә алар өчен таяна торган урыннар (шундый мендәрле матур табын) әзерләде, һәрберсенә (өстәлдәге тәкъдим ителгән җимешләрне әрчеп турау өчен) берәр пычак бирде һәм (алар каршыларындагы җимешләрне әрчеп-турап торган арада, Йосыфка): "Алар янына чык", – диде. Хатыннар аны күргәч, аны олыладылар һәм (аның гүзәл йөзе каршында үз-үзләрен онытып,) кулларын кискәләделәр һәм: "Аллаһ сакласын! Бу бит – кеше түгел. Бу – хөрмәтле бер фәрештәдер (башка нәрсә була алмас)", – диделәр»** («Юсуф», 31).

Аяти кәримәдәге «Таяна торган урыннар (мендәрләр)» мәгънәсен белдергән «мүттәкәән» сүзе, «аш-су мәҗлесе» дигәнне дә белдерә. Чөнки бу тәкәббер халык, үзләренең гореф-гадәтләренчә, ашаганда-эчкәндә һәм гәпләшкәндә аркаларына мендәр куеп, терәлеп ята торган була. Шунлыктан ярым яткан хәлдә арка терәп, ашау-эчү гадәте тыела. Чыннан да, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «*Мин берәр урынга таянып ашамыйм*», – дип әйткән (Бохари, «Әтгыймә», 13).

Хәзрәти Гайшә радыйаллаһу ганһә Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йөз-чырай матурлыгын сурәтләгәндә, Аны Йосыф галәйһис-сәләәм белән чагыштырып ала:

وَلَوْ سَمِعَ أَهْلُ مِصْرَ أَوْصَافَ حَدِّهِ لَمَا بَذَلُوا فِي سَوْمِ يُوسُفَ مِنْ نَقْدٍ
لَوَائِمُ زُلَيْخَا لَوْ رَأَيْنَ جَبِينَهُ لآثَرْنَ بِالْقَطْعِ الْقُلُوبَ عَلَى الأَيْدِ

«Мисыр халкы Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең йөз-бите нинди матур икәнен ишетсәләр, Йосыф галәйһис-сәләәм өчен сатулашканда бер тиен дә тотмаслар иде. Зөләйханы яманлаган хатыннар Рәсүл Әкрәмнең нурлы йөзен күрсәләр, куллары урынына йөрәкләрен кисәрләр иде».

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, тормышы да йөз-кыяфәте кебек күркәм булсын өчен, һәрдаим дога кыла. Күзгегә караганда, Ул әхлакый матурлыкның мөһимлегенә басым ясый һәм:

*«Аллаһым! Яратылышымны күркәм кылган кебек әхлагымны да яхшырт!»*

*«Йә Раббы! Мине әхлакның иң күркәменә ирештер! Шөбһәсез, аңа бары тик Син генә ирештерә аласың!»* – дип дога укый торган була (Ибне Хаҗәр, «Фәтхул-Бари», X, 456).

Йосыфның күз камаштыргыч чибәрлегенә Мисыр хатын-кызларының шаккатуын күргәч, Зөләйха:

قَالَتْ فَذلِكُنَّ الَّذِي لُمْتُنَّنِي فِيهِ وَلَقَدْ رَاوَدْتُهُ عَنْ نَفْسِهِ فَاسْتَعْصَمَ
وَلَئِنْ لَمْ يَفْعَلْ مَا آمُرُهُ لَيُسْجَنَنَّ وَلَيَكُونًا مِنَ الصَّاغِرِينَ

**«Әйтте: “Бу – ул кеше (егет), сез аның аркасында мине гаепләдегез. Мин аны кызыктырдым, әмма ул (гыйффәтле) сакланды. Әгәр ул минем әмер иткән бу эшне эшләмәсә, һичшиксез, зинданга ябылачак һәм түбәнсетелгән кешеләрдән булачак”»** («Юсуф», 32).

Мисыр урамнарында йөргәндә, йөзе кояш кебек яктылык, нур сипкән һәм ундүртенче кичәдәге тулган айдан да матуррак булган Йосыф галәйһис-сәләәм, хатын-кызлар фетнәсе каршында Аллаһтан бик нык куркып, кулларын догага күтәрә һәм, үзен яклау-саклау сорап, Раббысына ялвара. Чөнки Хак Тәгаләгә карата гафил йөрәкле хатын-кызларның хәйлә-мәкере шайтан тозакларыннан да куркынычрак.

قَالَ رَبِّ السِّجْنُ أَحَبُّ إِلَيَّ مِمَّا يَدْعُونَنِي إِلَيْهِ وَإِلَّا تَصْرِفْ عَنِّي
كَيْدَهُنَّ أَصْبُ إِلَيْهِنَّ وَأَكُنْ مِنَ الْجَاهِلِينَ

**«(Йосыф) әйтте: “И, Раббым! Зиндан болар өндәгән нәрсәдән миңа сөеклерәк. Әгәр Син аларның хәйләләрен миннән алмасаң, мин аларга авышырмын да, наданнардан булырмын”»** («Юсуф», 33).

Кайбер күренекле затлар болай дигән:

«Нәфескә юл биреп, ягъни нәфес теләкләрен үтәп, аның явызлыгыннан котылу мөмкин түгел. Аннан котылу чарасы – Аллаһка сыгынып, Аның әмерләренә буйсыну. Йосыф галәйһис-сәләәм дә, Раббысына сыгынып, котылуга ирешә».

فَاسْتَجَابَ لَهُ رَبُّهُ فَصَرَفَ عَنْهُ كَيْدَهُنَّ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ

**«Раббысы (догасын) кабул итте, аларның (хатыннарның) хәйләсен аңардан алды. Һичшиксез, Ул – Ишетүче, Белүче»** («Юсуф», 34).

Аллаһ Тәгалә якламаганда, һичбер йөрәк, хәтта теге яки бу Пәйгамбәрнең йөрәге кадәр камиллеккә ирешсә дә, дөньялыктагы хәйлә-мәкерләрдән, төрле теләк-омтылышларга бирелүдән, нәфес котыртуларыннан һәм шайтанның вәсвәсәләреннән имин булмас, үз-үзен саклый алмас! Әйтик, югарыда искә алынган аяти кәримәдәге «Раббысының борһаны» сүзләре дә әнә шул хикмәтне белдерә.

Димәк, бәндә буларак, безгә йөкләнгәне – нәфесебезнең хәйләсенә һичкайчан бирешмәячәгебезгә ышанмыйча, һәрдаим уяу булу һәм, бу мәсьәләдәге гаҗизлегебезне аңлап, Аллаһка сыгыну.

### Зиндан

Йосыф галәйһис-сәләәмнең догасы кабул булу сәбәпле, аны төрмәгә озаталар:

ثُمَّ بَدَا لَهُمْ مِنْ بَعْدِ مَا رَأَوُا الْآيَاتِ لَيَسْجُنُنَّهُ حَتَّى حِينٍ

**«Шуннан, дәлилләр күргәннән соң, алар бервакытка кадәр аны (Йосыфны) ябарга булдылар»** («Юсуф», 35).

Йосыфның өстендәге киемнәре салдырылып, аңа тупас йоннан тукылган хырка (алгы яка тирәсе ачык, җиңле плащка охшаш кием-салым) кидерелә, аякларына тимер зынҗыр тагыла. Йосыф галәйһис-сәләәм төрмә ишегенә якын килгәч, башын ия дә «Бисмиллаһ» дип, эчкә уза. Аның тирә-ягын уратып алалар, ә ул үзе исә елый башлый. Җәбраил галәйһис-сәләәм килеп, ник елаганын сорый. Йосыф намаз укый алырлык урын таба алмаганга елаганын белдергәч, Җәбраил галәйһис-сәләәм аңа: «Үзең кайда телисең, шунда намаз укы! Аллаһ төрмәнең эчендә һәм тышында кырык аршын җирне синең өчен пакь итте», – дип хәбәр итә.[102]

102. Әүвәлге пәйгамбәрләр һәм өммәтләрнең һәр җирдә гыйбадәт кылуын шәригатьләре рөхсәт итми. Алар махсус урыннарда гына гыйбадәт кыла ала. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәхесе хакына, ягъни мөбарәк затына хас сыйфатлар хакына, бөтен җир йөзе Аның өммәте өчен гыйбадәт урынына әйләнә һәм пакь дип санала. Аллах Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «…Җир йөзе минем өчен мәчет ителде һәм пакь кылынды...» – дип әйткән (Бохари, «Тәяммүм», 1).

وَدَخَلَ مَعَهُ السِّجْنَ فَتَيَانِ قَالَ أَحَدُهُمَآ إِنِّي أَرَانِي أَعْصِرُ خَمْرًا وَقَالَ الْآخَرُ إِنِّي أَرَانِي أَحْمِلُ فَوْقَ رَأْسِي خُبْزًا تَأْكُلُ الطَّيْرُ مِنْهُ نَبِّئْنَا بِتَأْوِيلِهِ إِنَّا نَرِيكَ مِنَ الْمُحْسِنِينَ. قَالَ لَا يَأْتِيكُمَا طَعَامٌ تُرْزَقَانِهِ إِلَّا نَبَّأْتُكُمَا بِتَأْوِيلِهِ قَبْلَ أَنْ يَأْتِيَكُمَا ذٰلِكُمَا مِمَّا عَلَّمَنِي رَبِّي إِنِّي تَرَكْتُ مِلَّةَ قَوْمٍ لَا يُؤْمِنُونَ بِاللّٰهِ وَهُمْ بِالْآخِرَةِ هُمْ كَافِرُونَ

**«Аның белән бергә зинданга ике егет тә ябылды. Аларның берсе: “Һичшиксез, мин (төшемдә) үземнең хәмер (өчен йөзем) сыкканымны күрдем”, – диде. Икенчесе: “Һичшиксез, мин үземне күрдем, башым өстендә икмәк йөртәмен, кошлар исә шуны ашыйлар. Безгә моның тәгъбирен хәбәр итче. Һичшиксез, без сине игелек ияләреннән дип күрәбез”, – диде. (Йосыф) әйтте: “Сезгә ашатыласы ризыкларыгыз килеп тә җитмәс, мин сезгә аңарчы аның мәгънәсен хәбәр итәрмен. Бу – Раббымның миңа өйрәткән нәрсәләреннән. Һичшиксез, мин Аллаһка инанмаган һәм Ахирәтне инкяр иткән бер кавемнең динен кире кактым”»** («Юсуф», 36–37).

Бу ике егетнең төрмәгә эләгүләре турында мондый риваять бар:

Мисырның күренекле кешеләреннән гыйбарәт бер төркем, Мәлик (патша) Рәййан ибне Вәлидне агулап үтереп, үз араларыннан сайлап алынган берәрсен аның урынына куярга тели. Бу максатны күздә тотып, Мәликкә табын әзерләүче ике кешене – берсе ашчы, берсе ширбәтче – төрле вәгъдәләр белән үз якларына аударалар. Аларны Мәликнең ризыгына һәм эчемлегенә агу кушарга котырталар.

Ширбәтче, бу эшнең яманлыгын аңлап, агу салудан баш тарта. Ашчы исә бу әшәкелекне эшләргә алына. Табын әзерләп, Мәлик ашамлыкка кулын сузгач, ширбәтче: «Әй, Мәлик! Сак бул, ашама аны, чөнки ул ризык агулы», – дип кисәтә.

Ашчы исә: «Әй, Мәлик! Сак бул, эчмә аны, чөнки ул эчемлек агулы», – дип әйтә.

Шуннан соң Мәлик ширбәтчегә табындагы эчемлекләрне эчәргә куша. Тегесе исә һич икеләнеп тормыйча, эчеп тә куя. Аннары Мәлик ашчыга дәшә һәм ризыкларны ашап карарга әмер бирә. Ләкин ашчы бернәрсә дә ашамый. Ул ашамлыкны бер хайванга ашаткач, бу хайван шундук үлеп китә. Әлеге вакыйгадан соң ашчы да, ширбәтче дә төрмәгә озатыла. Зинданда чакта аятьтә искә алынган төшләрне күрәләр (Куртуби, «әл-Җамигъ», IX, 189).

Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм төрмәдә үзе белән бергә утырган бу ике егетне тәүхид иманга чакырырга тели. Аларны төшләрен юрап-аңлатып бирер алдыннан, үзенең хак дин юлында икәнлеген, үзендәге гыйлемнең Җәнабел-Хак тарафыннан насыйп ителгәнен һәм мисырлыларның ялгыш юлда

булуын белдерә. Егетләрне тәүхид гакыйдәсенә хәзерләп, аларны хак дингә килергә өнди.

Монда сабак алынырга тиешле мәсьәлә – мөэмин кешенең иң авыр шартларда да «әмри бил-мәгъруф вә нәһйи ганил-мүнкәр», ягъни игелеккә чакырып, яманлыктан тыярга тырышу эшен кире какмаска, туктатмаска тиешлеге.

Менә шушы һәм аннан соң килгән өч аять Хәзрәти Йосыфның иманга өндәве белән бәйле:

وَاتَّبَعْتُ مِلَّةَ آبَآئِي إِبْرَاهِيمَ وَإِسْحقَ وَيَعْقُوبَ مَا كَانَ لَنَا أَنْ نُشْرِكَ بِاللَّهِ مِنْ شَيْءٍ ذلِكَ مِنْ فَضْلِ اللهِ عَلَيْنَا وَعَلَى النَّاسِ وَلَكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَشْكُرُونَ. يَا صَاحِبَيِ السِّجْنِ أَأَرْبَابٌ مُتَفَرِّقُونَ خَيْرٌ أَمِ اللهُ الْوَاحِدُ الْقَهَّارُ. مَا تَعْبُدُونَ مِنْ دُونِهِ إِلَّا أَسْمَاءً سَمَّيْتُمُوهَا أَنْتُمْ وَآبَآؤُكُمْ مَا أَنْزَلَ اللهُ بِهَا مِنْ سُلْطَانٍ إِنِ الْحُكْمُ إِلَّا لِلَّهِ أَمَرَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ ذلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ وَلَكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ.

**«Мин аталарым Ибраһим, Исхак вә Ягъкубның диненә иярдем. Безгә Аллаһка һичбер нәрсәне ширек кушарга ярамый. Бу (тәүхид иман) – Аллаһның безгә һәм кешеләргә карата фазылыннан, ләкин (ни кызганыч) кешеләрнең күбесе шөкер итмиләр.**

**И, минем зиндан иптәшләрем! Бик күп аерым-аерым раббыларыгыз яхшыракмы, әллә бердәнбер һәм көчле булган Аллаһмы? Аны (Аллаһны) ташлап, сез үзегез һәм аталарыгыз уйлап тапкан исемнәргә генә табынасыз. Алар (аларга табыну) хакында Аллаһ бернинди дәлил дә иңдермәде. Хөкем – Аллаһныкы гына. Ул Үзеннән башка берәүгә дә гыйбадәт итмәвегезне әмер итте. Бу – дөрес дин, ләкин кешеләрнең күбесе белмиләр»** («Юсуф», 38–40).

**Хәзрәти Йосыфның төш юравы**

Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм үзеннән төшләрен тәгъбирләп бирүен сораган ике төрмәдәшен тәүхид иманга чакырганнан соң, аларга болай дип сүз ката:

يَا صَاحِبَيِ السِّجْنِ أَمَّا أَحَدُكُمَا فَيَسْقِي رَبَّهُ خَمْرًا وَأَمَّا الْآخَرُ فَيُصْلَبُ فَتَأْكُلُ الطَّيْرُ مِنْ رَأْسِهِ قُضِيَ الْأَمْرُ الَّذِي فِيهِ تَسْتَفْتِيَانِ.

**«И, минем зиндан иптәшләрем! Инде (төшләрегез мәсьәләсендә) сезнең берегезгә килгәндә, ул хуҗасына хәмер эчерәчәк. Әмма икенчегез**

**тәрегә кагылачак һәм кошлар аның башыннан ашаячак. Үзе турында хөкем сораган эшегез хәл ителгән»** («Юсуф», 41).

وَقَالَ لِلَّذِي ظَنَّ أَنَّهُ نَاجٍ مِنْهُمَا اذْكُرْنِي عِنْدَ رَبِّكَ فَأَنْسِيهُ الشَّيْطَانُ
ذِكْرَ رَبِّهِ فَلَبِثَ فِي السِّجْنِ بِضْعَ سِنِينَ

**«Ул икесе арасыннан һичшиксез котылачагын белгән кешегә: “Мине хуҗаң янында телгә ал (Гаепсез икәнлегемне исенә төшер. Бәлки, мине моннан чыгарыр)”, – диде. Әмма шайтан аңа хуҗасына хәтерләтергә оныттырды, шул сәбәпле ул (Йосыф) берничә ел зинданда калды»** («Юсуф», 42).

Чынбарлыктагы нәтиҗә нәкъ Йосыф галәйһис-сәләәм юраганча була. Ширбәтче, зинданнан котылып, иске вазифасына кайта. Ашчы исә җәзалап үтерелә.

Кайбер мөфәссирләр фикеренчә, Йосыф галәйһис-сәләәмнең Раббысыннан кала башка берәүдән ярдәм соравы гайрәтуллаһка – Аллаһның үз хакын яклау сыйфатына кагыла. Бу хәл Пәйгамбәрләр өчен бер хата булып тора. Шушы хатасы аркасында Хәзрәти Йосыф, биш ел ирексезлектә гомер кичергәннән соң, тагын җиде ел зинданда кала. Шул рәвешле төрмә срогы унике елга сузыла.

Риваятькә күрә, төрмәдән иреккә чыгучылар Йосыф галәйһис-сәләәм янына бик еш килеп йөри, аның хәлләрен сорашалар, озын-озак сөйләшеп утыралар. Бер көнне төрмәнең баш сакчысы Йосыф галәйһис-сәләәм белән гәпләшкән чакта: «И, Йосыф! Сине шулкадәр нык яратам, һичнәрсәне сине сөйгән кадәр сөймимдер», – дип әйтә. Йосыф галәйһис-сәләәм исә: «Миңа карата сөюеңнән Аллаһка сыгынам!» – дип җавап кайтара. Баш төрмә сакчысы бу сүзләренең сәбәбе белән кызыксынгач, Йосыф: «Әтием мине бик яратты, шуннан соң туганнарым мине коега ташлады; Зөләйха сөйде – мине төрмәгә яптылар, хәзер менә син дә сөясең, кем белә, мине тагын кая ыргытырлар!?» – ди.

Малик ибне Динардан риваять кылына:

Йосыф галәйһис-сәләәм шәрабчыга: «Мине хуҗаң янында искә ал!» – дигәч, Аллаһ Тәгаләдән мондый хәбәр килә: «Әй, Йосыф! Миннән башка яклаучы эзләдең. Мин исә синең төрмәдәге вакытыңны озайтачакмын!» Шуннан соң Йосыф галәйһис-сәләәм елап җибәрә һәм: «И, Раббым! Җәфа-кайгылар күплеге аркасында йөрәгем арыды, катыланды; инде моннан соң миннән башка мондый сүз чыкмас!» – дип әйтә.

Хәсән Басри хәзрәтләре бу риваятьне укыган саен, елый-елый, болай дия торган була: «Башыбызга берәр эш төшкәч, кеше янына чабабыз. Бу гамәлебез белән безне нинди ачы язмыш көтә соң?!»

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Аллаһ туганым Йосыфка рәхмәтле булсын! Ул шәрабчыга: «Мине хуҗаң янында искә ал!» – дип әйтмәгән булса, төрмәдән биш елдан соң тагын җиде елга калмаячак иде»*, – дип әйткән (Бурсәви, «Рухул-Бәян», IV, 264).

Ләкин Җәнабел-Хакның Пәйгамбәрләргә һәм әүлияларга җибәргән көчсезлек хәле, кыенлыклар һәм төрле борчу-мәшәкатьләр аларга җәза итеп түгел, ә бүләк итеп бирелә.

Хәдис-шәрифтә: *«Аллаһ бер колын сөйгәндә, аның өстенә бәлаләрне чәчәр дә чәчәр!..»* – дип әйтелә (Гали әл-Муттакый, «Кәнзүл-Уммал», III, 334/6811).

Әбү Сәгыйд әл-Худри радыйаллаһу ганһе Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезне Ул авырган чакта зиярәт кыла һәм Аңа кичерергә туры килгән бик көчле авырту-сызлануларга шаһит була. Әбү Сәгыйд әл-Худри болай дип искә ала: «Кулымны Аның өстенә куйдым, кайнарлыгын юрган аркылы да сизә идем. «И, Аллаһның Рәсүле, тәнегез бик кайнар!» – дидем.

*«Без (Пәйгамбәрләр) шундый. Бәлаләр безгә катлы-катлы килер, моңа каршы әҗерләре дә катлы-катлы бирелер»*, – дип белдерде.

«И, Аллаһның Рәсүле! Кешеләрдән кемнәр иң күп бәлагә дучар ителә?» – дип сорадым. *«Пәйгамбәрләр!»* – дип җавап бирде. «Аннары кемнәр?» – дидем. *«Аннары изгеләр!»* – диде һәм әлеге аңлатмасына өстәп куйды: *«Алардан кайберләре шулкадәр фәкыйрьлеккә эләгер ки, үзен каплаган тупас киемнән кала бернәрсә дә таба алмас. Сез муллыкка сөенгән кебек, алар бәла-авырлыкка сөенерләр»* (Ибне Мәҗә, «Фитән», 23).

**Мисыр патшасының төше**

Аяти кәримәдә кыйссаның дәвамы түбәндәгечә тасвирлана:

وَقَالَ الْمَلِكُ إِنِّي أَرَى سَبْعَ بَقَرَاتٍ سِمَانٍ يَأْكُلُهُنَّ سَبْعٌ عِجَافٌ وَسَبْعَ سُنْبُلاَتٍ خُضْرٍ وَأُخَرَ يَابِسَاتٍ يَا أَيُّهَا الْمَلأُ أَفْتُونِي فِي رُؤْيَايَ إِنْ كُنْتُمْ لِلرُّؤْيَا تَعْبُرُونَ. قَالُوا أَضْغَاثُ أَحْلاَمٍ وَمَا نَحْنُ بِتَأْوِيلِ الْأَحْلاَمِ بِعَالِمِينَ. وَقَالَ الَّذِي نَجَا مِنْهُمَا وَادَّكَرَ بَعْدَ أُمَّةٍ أَنَا أُنَبِّئُكُمْ بِتَأْوِيلِهِ فَأَرْسِلُونِ. يُوسُفُ أَيُّهَا الصِّدِّيقُ أَفْتِنَا فِي سَبْعِ بَقَرَاتٍ سِمَانٍ يَأْكُلُهُنَّ سَبْعٌ عِجَافٌ وَسَبْعِ سُنْبُلاَتٍ خُضْرٍ وَأُخَرَ يَابِسَاتٍ لَعَلِّي أَرْجِعُ إِلَى النَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَعْلَمُونَ.

**«Хөкемдар әйтте: “Һичшиксез, мин (төшемдә) җиде арык сыерның җиде көр сыерны ашаганын күрдем. Янә җиде яшел башак белән (җиде)**

**коп-коры бүтәннәрен (күрдем). И, олуг кешеләр! Әгәр сез төш юрый алган кешеләр булсагыз, миңа төшем турында хөкем бирегез”». Алар (тирәсендәге камнар): «(Сез күргәннәр) бәйләнешсез төшләр. Без ул төшләрне юрый алмыйбыз», – диделәр. Әмма теге икәве арасыннан котылганы һәм (шулкадәр) вакыттан соң (Йосыфны) хәтерләгәне: «Аны сезгә мин хәбәр итә алам. Мине (зинданга) җибәрегез», – диде. (Зинданга килгәч, болай диде:) «И, Йосыф! И, тугры! (Шушы читен төш турында безгә аңлатмасын белдер) Җиде арык сыерны ашаган җиде көр сыер хакында безгә хөкем бир, һәм җиде яшел башак белән коп-коры булган бүтәннәре (нәрсә белдерә ала). Мин кешеләргә кайтыйм да, (файдалы тәгъбиреңне тапшырыйм, бәлки, алар (дөреслекне) белерләр»** («Юсуф», 43–46).

Йосыф галәйһис-сәләәм Аллаһ Тәгалә аңа биргән гыйлем ярдәмендә төшне болай дип юрый:

قَالَ تَزْرَعُونَ سَبْعَ سِنِينَ دَأَبًا فَمَا حَصَدْتُمْ فَذَرُوهُ فِي سُنْبُلِهِ إِلَّا قَلِيلًا مِمَّا تَأْكُلُونَ. ثُمَّ يَأْتِي مِنْ بَعْدِ ذٰلِكَ سَبْعٌ شِدَادٌ يَأْكُلْنَ مَا قَدَّمْتُمْ لَهُنَّ إِلَّا قَلِيلًا مِمَّا تُحْصِنُونَ. ثُمَّ يَأْتِي مِنْ بَعْدِ ذٰلِكَ عَامٌ فِيهِ يُغَاثُ النَّاسُ وَفِيهِ يَعْصِرُونَ.

**«Гадәтегезчә, җиде ел иген чәчәрсез. Шуннан ашаганыгызның бик азыннан кала, нәрсә урсагыз да, аны башакта калдырыгыз (сакларсыз). Шуннан бик авыр җиде ел киләчәк. Алар, (чәчүлек орлык итеп) саклаган бик аз нәрсәдән башка, әзерләгән нәрсәләрегезне ашап бетерәчәк. Шуннан моның артыннан бер ел киләчәк ки, кешеләргә анда яңгыр белән ярдәм булачак (авырлыктан котылачак) һәм янә (мул-мул җиләк-җимеш) сыгачаклар»** («Юсуф», 47–49).

Хәзрәти Йосыфның төшне аңлатмасыннан тынычланып, бик сөенгән хөкемдар, аны бүләкләргә теләи:

وَقَالَ الْمَلِكُ ائْتُونِي بِهِ فَلَمَّا جَاءَهُ الرَّسُولُ قَالَ ارْجِعْ إِلَى رَبِّكَ فَاسْأَلْهُ مَا بَالُ النِّسْوَةِ الَّتِي قَطَّعْنَ أَيْدِيَهُنَّ إِنَّ رَبِّي بِكَيْدِهِنَّ عَلِيمٌ.

**«Хөкемдар: “Аны миңа китерегез!” – диде. Илче аңа килгәч, (Йосыф): “Әфәндеңә кайт та, кулларын кискәләгән хатыннарның хәле турында сора үзеннән. Һичшиксез, минем Раббым – аларның (ул хатыннарның) хәйләләрен белүче”, – диде»** («Юсуф», 50).

Хәзрәти Йосыф, әдәп саклап, анда Зөләйханың исемен телгә алмый. Үзенә карата дошманлык хисенең бик көчле булуына ышанганлыктан, аның яңа берәр мәкер кылуыннан да саклана. Хөкемдар ул хатыннарны җыя да:

قَالَ مَا خَطْبُكُنَّ إِذْ رَاوَدْتُنَّ يُوسُفَ عَنْ نَفْسِهِ قُلْنَ حَاشَ لِلَّهِ مَا عَلِمْنَا عَلَيْهِ مِنْ سُوءٍ قَالَتِ امْرَأَةُ الْعَزِيزِ الْآنَ حَصْحَصَ الْحَقُّ أَنَا رَاوَدْتُهُ عَنْ نَفْسِهِ وَإِنَّهُ لَمِنَ الصَّادِقِينَ.

**«Әйтте: “Сез Йосыфны кызыктырганыгыз (вакытта аңа нинди дәгъвагыз булуы) хакында ни диярсез?” (Алар) әйттеләр: “Аллаһ сакласын! Без аның хакында бернинди начарлык та белмибез (күрмәдек)”. (Шулвакыт) падишаһның хатыны әйтте: “Хәзер хак ачыкланды. Мин аны кызыктырдым. Һичшиксез, ул – дөрес кешеләрдән” (дип үзен ача)»** («Юсуф», 51).

Йосыф галәйһис-сәләәм бу гамәленең сәбәбен ачыклаганда, болай ди:

ذٰلِكَ لِيَعْلَمَ أَنِّي لَمْ أَخُنْهُ بِالْغَيْبِ وَأَنَّ اللَّهَ لَا يَهْدِي كَيْدَ الْخَائِنِينَ

**«Бу – ул минем аның (вәзир) югында хыянәт кылмавымны һәм Аллаһ хыянәтчеләрнең хәйләсен уңышка ирештермәячәген белсен өчен»** («Юсуф», 52).

Җәнабел-Хак мәкерле затларны, хәйлә белән эш итүчеләрне һәм хаиннәрне һич яратмавын аяти кәримәдә болай дип раслый:

إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الخَائِنِينَ

**«...Һичшиксез, Аллаһ хыянәтчеләрне бер дә сөйми»** («әл-Әнфәл», 58).

Иң зур хыянәт исә – Аллаһка һәм Рәсүленә каршы кылынган хаинлек. Җәнабел-Хак бу хакта безне, бәндәләрне, ачык рәвештә кисәтеп куя:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَخُونُوا اللَّهَ وَالرَّسُولَ وَتَخُونُوا أَمَانَاتِكُمْ وَأَنْتُمْ تَعْلَمُونَ

**«И, иман китерүчеләр! Белә торып, Аллаһка һәм Аның Рәсүленә хыянәт итмәгез, әманәтләрегезгә дә хыянәт итмәгез»** («әл-Әнфәл», 27).

Бәндәләрнең хокукларын бозу, бәндә хакына керү юлы белән, Аллаһ Тәгалә кушканнарга һәм Ул тыйганнарга хыянәт иткән, нәтиҗәдә исә үз әманәтләренә хыянәтләрен аңлаган «Дарван әһелләре»нең гыйбрәтле кыйссасы хыянәтнең зарары хаиннәрнең үзләренә генә әйләнеп кайтачагын бик аңлаешлы, ачык сурәтләп бирә.

### Дарван кыйссасы

Риваятькә күрә, юмарт бер йәмәнленең Сана тирәсендә йөзем, хөрмә һәм иген бакчасы була. Бу юмарт кеше уңыш җыйган вакытларда фәкыйрьләргә, мөһаҗирләргә һәм зәгыйфьләргә гошер өлешен мулдан аера, арттырып бирә. Үлем сәгате якынайгач, улларын җыеп, бу эшне дәвам итәргә васыять әйтә.

Ләкин әлеге изге зат вафат булгач, балаларының күзен малга хирыслык томалый, алар үз араларында: «Гаиләбез бик зур, кеше күп, мал исә аз. Хәзер инде фәкыйрьләргә бернәрсә дә бирмик! Алар килеп сораганчы, уңышны җыеп алыйк...» – дип вәгъдәләшәләр.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү аларның мондый яман ниятләренә каршы, бакчаларын яндырып, кап-кара хәрабә хәленә калдыра. Ул зур бакча һич танымаслык рәвешкә керә. Бу хәлне күргәч, саран балалар: «Әллә ялгыш урынга килдекме?» – дип аптырашта кала.

Югыйсә аталарының гошерне юмарт өләшеп, мохтаҗларның догасын алуы бакчага бәрәкәтне артыгы белән биреп тора. Барлык фәкыйрьләр һәм мөһаҗирләр шул бакчадан файда күрәләр. Тик аталары ярлыларга тараткан гошер балаларының күзенә зур булып күренә һәм аны һич бирергә теләмиләр. Алар Аллаһ ул бакчага биргән бәрәкәтнең каян килгәнен белмиләр-аңламыйлар, чөнки гафләт аларның йөрәкләрен сукырайткан була.

Шуңа күрә дә Җәнабел-Хак: **«Гафилләрдән булма!»** – дип кисәтә («әл-Әгъраф», 205).

«Дарван әһелләре» кыйссасы дип танылган бу вакыйга Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә бәян кылына:

إِنَّا بَلَوْنَاهُمْ كَمَا بَلَوْنَا أَصْحَابَ الْجَنَّةِ إِذْ أَقْسَمُوا لَيَصْرِمُنَّهَا مُصْبِحِينَ.
وَلَا يَسْتَثْنُونَ. فَطَافَ عَلَيْهَا طَائِفٌ مِنْ رَبِّكَ وَهُمْ نَائِمُونَ. فَأَصْبَحَتْ كَالصَّرِيمِ. فَتَنَادَوْا
مُصْبِحِينَ. أَنِ اغْدُوا عَلَى حَرْثِكُمْ إِنْ كُنْتُمْ صَارِمِينَ. فَانْطَلَقُوا وَهُمْ يَتَخَافَتُونَ. أَنْ لَا
يَدْخُلَنَّهَا الْيَوْمَ عَلَيْكُمْ مِسْكِينٌ. وَغَدَوْا عَلَى حَرْدٍ قَادِرِينَ.

**«Һичшиксез, Без (үз вакытында) бакча ияләрен сынаганыбыз кебек, аларны да (Аллаһ Рәсүленә каршы чыккан мөшрикләрне) сынадык. Менә алар (бакча ияләре) иртә җитүгә, (һичкемгә күренмичә) тулысынча аны (уңышларын) җыеп алачакларына ант иттеләр. Алар өстәп (искәрмә дә) әйтмәделәр ("Иншә Аллаһ", дип әйтмиләр һәм фәкыйрьләрнең өлешен аермыйлар). Алар йоклаган вакытта Раббыңнан (җибәрелгән) уратып ала торган бер бәла аны йөреп чыкты. Иртән кисеп ташланган кебек булды. (Бу тарафта исә) алар иртән бер-берсенә дәштеләр. "Бакчагызга барыгыз, әгәр уңыш җыярга җыенган кешеләр булсагыз". Алар, әкрен генә сөйләшә-сөйләшә, анда кузгалдылар. "Бүген (анда) бер генә фәкыйрь дә сезгә (арабызга) кермәсен". (Әйе, ярлыларга ярдәм итәргә хәлләре җиткән килеш, аларны ярдәмнән мәхрүм итү нияте белән) көчле икәнлекләрен санап, иртән юлга чыктылар»** («әл-Каләм», 17–25).

Бакчаларына барып җитеп, саранлыкларының һәм хәйләкәрлекләренең авыр нәтиҗәсен күргәч, үкенеч утында яналар. Җәнабел-Хак аларның аптырашта калуын һәм үкенечләрен болай тасвирлый:

فَلَمَّا رَأَوْهَا قَالُوا إِنَّا لَضَالُّونَ. بَلْ نَحْنُ مَحْرُومُونَ. قَالَ أَوْسَطُهُمْ أَلَمْ أَقُلْ لَكُمْ لَوْلَا تُسَبِّحُونَ. قَالُوا سُبْحَانَ رَبِّنَا إِنَّا كُنَّا ظَالِمِينَ. فَأَقْبَلَ بَعْضُهُمْ عَلَى بَعْضٍ يَتَلَاوَمُونَ. قَالُوا يَا وَيْلَنَا إِنَّا كُنَّا طَاغِينَ. عَسَى رَبُّنَا أَنْ يُبْدِلَنَا خَيْرًا مِنْهَا إِنَّا إِلَى رَبِّنَا رَاغِبُونَ.

**«Әмма аны күргәч, әйттеләр: “Без юлдан язганбыз. (Ялгыш җиргә килмәгәнлекләрен аңлагач) юк! Без мәхрүм ителдек!”» Араларындагы иң уртачалары (инсафлылары): «Мин сезгә (Аллаһны) тәсбих итәргә кирәк, димәгән идемме?» – диде. Алар: «Аллаһ пакь! (дип Раббызны тәсбих итәбез). Һичшиксез, без (үз-үзебезгә) золым эшләдек», – диделәр. Алар бер-берсен шелтәли башладылар. (Ахырда) әйттеләр: «Ни үкенеч безгә! Без чиктән ашкан кешеләр булдык. Бәлки, Раббыбыз безгә моның урынына моннан да яхшырагын бирер. Һичшиксез, без (инде) Раббыбызга кайтабыз (Аның ризалыгын телибез)»** («әл-Каләм», 26–32).

Әлеге аятьләрдә ярлы-ябагайга, йортсыз-җирсезгә гошер өлешен бирмәс өчен хәйләгә барган мәрхәмәтсез бакча хуҗаларының кайгылы язмышын Җәнабел-Хак, бер гыйбрәт итеп, шундый күркәм рәвештә белдерә. Йөрәкләрдәге барлык ниятләр дә Җәнабел-Хакка билгеле. Аның кодрәте, бөеклеге һәрнәрсәне колачлый.

Аллаһ Тәгалә бу кыйссаны менә шушы мөһим кисәтү белән тәмамлый:

كَذَلِكَ الْعَذَابُ وَلَعَذَابُ الْآخِرَةِ أَكْبَرُ لَوْ كَانُوا يَعْلَمُونَ.

**«Газап шундый. Ахирәт газабы исә моннан да зуррак. Әгәр белсәләр иде!»** («әл-Каләм», 33).

### Хәзрәти Йосыфның зирәклеге

Мәлик хакыйкатьне яхшылап төшенмичә, мәсьәләнең асылы җитәрлек аңлашылмыйча һәм аның төрмәгә нахак утыртылуы һәркем өчен дә анык булмыйча торып, Йосыф галәйһис-сәләәм зинданнан чыгарга ашыкмый. Акылын эшкә җигеп, сабыр һәм җитди мөнәсәбәт күрсәтеп, аннан көнләшкән бәндәләрнең эшне тагын да бутап, чуалтып җибәрүенә дә комачаулый. Аңа тагылган бөтен гаепләрнең яла һәм ялган икәнлеген исбатлап, төхмәттән[103] тәмам котылгач, төрмәдән чыгарылу тәкъдимен кабул итә.

103. Төһмәт – катгый, анык дәлил белән исбатланмаган килеш, бер гаеп эш эшләгән дип саналу яки шундый шик астына алыну халәте.

Шунлыктан һәр мөселман, Йосыф галәйһис-сәләәмнең мондый зирәк гамәленнән үрнәк алып, үз өстеннән шик-шөбһәне алып ташлау һәм төхмәт урыннардан саклану мәсьәләсендә бик игътибарлы һәм җитди булырга тиеш. Ислам галимнәре дә мөэминнәргә шикле урыннардан сакланырга, тыелырга кирәклеген белдерә.

Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе: «Кем төхмәт юлларга аяк басса, шул төхмәткә дучар ителер», – дип әйткән.

Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәмнең төхмәттән арыну мәсьәләсендәге нәфислегенә, җентеклелегенә охшаш эш-гамәлләрне Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезнең үрнәк тормышында да күрәбез. Мөэминнәрнең анасы Сафийя бинте Һуйәй радыйаллаһу ганһә Аллаһ Рәсүле белән булган бер вакыйганы искә ала:

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм игътикяфка кергән иде. Бер төнне Аны зиярәт кылырга бардым, сөйләшеп утырдык. Аннары өйгә кайтырга җыенгач, Ул мине озатып куярга кузгалды. Шулвакытта безгә ике әнсар очрады. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмне күргәч, алар тизрәк бу тирәдән китәргә теләделәр. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә: *«Акрынрак булыгыз. Янәшәмдәге кеше – Сафийя бинте Һуйәй ул»*, – диде.

Әнсарлар: «Рәсүленең килешмәгән гамәлләр кылуын кире кагып, Аллаһның пакьлеген тәсбих итәбез. йә, Рәсүлүллаһ!» – дигәч, Пәйгамбәр:

*«Шайтан кешенең тәнендә кан кебек йөреп торыр. Аның йөрәгегезгә берәр яманлык яки берәр шик кертүенә борчылдым»*, – дип әйтә (Бохари, «Игътикяф», 11; Мөслим, «Сәлам», 23–25).

Төхмәткә дучар булудан саклану гына түгел, башкалардан шикләнү мәсьәләсендә дә мөмкин кадәр тыелу кирәклеге турында Хак Тәгалә Коръәни-Кәримдә без, бәндәләрне, кисәтеп куя:

وَلَا تَقْفُ مَا لَيْسَ لَكَ بِهِ عِلْمٌ إِنَّ السَّمْعَ وَالْبَصَرَ وَالْفُؤَادَ كُلُّ أُولئِكَ كَانَ عَنْهُ مَسْؤُولًا

**«(Анык) белмәгән нәрсәләреңә иярмә. Һичшиксез, колак та, күз дә, күңел дә – боларның барысыннан да (кылганнары турында) соралачак»** («әл-Исра», 36).

Үзенең тулысынча гаепсез икәнлеген исбатлап, халыкның төхмәтеннән арынган Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм, нәфес мәкереннән янә Җәнабел-Хакка сыгынып, болай ди:

وَمَا أُبَرِّئُ نَفْسِي إِنَّ النَّفْسَ لَأَمَّارَةٌ بِالسُّوءِ إِلَّا مَا رَحِمَ رَبِّي إِنَّ رَبِّي غَفُورٌ رَحِيمٌ

**«(Шул ук вакытта) мин нәфесемне акламыйм. Һичшиксез, Раббымның рәхмәте булмаса, нәфес (булдыра алган кадәр көче белән) начар нәрсәләрне әмер итә. Һичшиксез, минем Раббым – (хаталарны яшереп) Гафу итүче, Рәхимле»** («Юсуф», 53).[104]

Бүтән бер аяти кәримәдә Аллаһ Тәгалә:

وَلَوْلَا فَضْلُ اللَّهِ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَتُهُ مَا زَكَى مِنْكُمْ مِنْ أَحَدٍ أَبَدًا
وَلَكِنَّ اللَّهَ يُزَكِّي مَنْ يَشَاءُ وَاللَّهُ سَمِيعٌ عَلِيمٌ

**«...Әгәр Аллаһның фазылы һәм рәхмәте сезгә булмаса, арагыздан берегез дә беркайчан да пакьләнмәс иде. Ләкин Аллаһ Үзе теләгән кешене пакь кыла. Аллаһ – Ишетүче, Белүче»**, – дип әйтә («ән-Нур», 21).

Бу тарафтан караганда, тәүбә-истигъфар, Аллаһка ялвару аша нәфес явызлыгыннан саклануны һәм ахирәткә йөз аклыгы белән күчү мөмкинлеген бәндә Раббыдан сорарга тиеш.

### Аллаһ колны солтан итә

Ахыр чиктә Хәзрәти Йосыфтагы нәфис сәясәт осталыгын, зирәклек һәм гайре табигый сәләтне тоеп алган Мәлик, аны дәрәҗәле урынга билгеләргә теле. Бу хәл аяти кәримәдә мондый рәвештә хәбәр ителә:

وَقَالَ الْمَلِكُ ائْتُونِي بِهِ أَسْتَخْلِصْهُ لِنَفْسِي فَلَمَّا كَلَّمَهُ قَالَ إِنَّكَ الْيَوْمَ لَدَيْنَا مَكِينٌ أَمِينٌ

**«Хөкемдар: “Аны миңа китерегез дә, мин аны үзем өчен якын кеше (киңәшче) итим”, – диде. Ул аның белән сөйләшкәч: “Син – бүген безнең янда зур дәрәҗә иясе һәм имин кешесең (киңәшчесең)”, – диде»** («Юсуф», 54).

Төрмәдән чыкканда, Йосыф галәйһис-сәләәм ишеккә болай дип язып куя: «Бу – бәлаләр йорты, тереләр кабере, дошманнар файдасына сөенеп көлә һәм дуслар сынала торган урын». Шуннан соң, госел алып, яңа киемнәрен кия. Аннары зиндандагылар өчен мондый дога кыла: «Аллаһым, аларга изгеләрнең йөрәкләрен насыйп ит һәм дусларының хәбәрләрен алардан яшермә!» Мәлик янына кергәч: «Аллаһым! Моңардан киләчәк хәерле нәрсәдән бигрәк, Синнән

104. «Юсуф» сүрәсенең 52 һәм 53 нче аятьләренең Зөләйха авызыннан әйтелгән сүзләр булу мөмкинлеге дә әйтелә. Ул очракта аларның эчтәлеге болай була: «Шул ук вакытта мин үземне акларга, нәфесемнең гаепсезлеген дәлилләргә җыенмыйм. Ягъни Йосыф артыннан барып, аңа хыянәт итмәгәнлегемне белсен, дип, хакыйкатьне раслаганда, үземне тулысынча пакь, гаепсез дип белдермим. Ни кылсам да, аның күз алдында эшләдем, аның артында, ягъни ул юк чакта аңа хыянәт итмәдем». Менә Газизнең хатыны шул рәвешле гаебен ача, тәүбә итә, вакыйганың чын асылын раслый. Хәзрәти Йосыфның Аллаһ катында билгеле гыйффәтлелеге һәм күңел сафлыгы әнә шулай халык өчен дә мәгълүм була.

хәерлене көтәм. Моның явызлыгыннан Синең гыйззәт һәм кодрәтеңә сыгынам», – диде.

Бу хөкемдар Йосыф галәйһис-сәләәмне сатып алган Газиз булмый. Зөләйханың ире Газиз, риваятькә күрә, Йосыф галәйһис-сәләәм төрмәдән чыкканчы ук җан тәслим кыла. Монда сүз бара торган хөкемдар, Гарәбстаннан килеп, дүрт йөз ел Мисырда хакимлек иткән династиядән фазыйләтле адәм була. Күп телләр белә. Йосыф галәйһис-сәләәмнең үзеннән дә күбрәк тел белүен күргәч, бик шакката. Шуннан соң төшенең аңлатмасын Йосыф галәйһис-сәләәмнең шәхсән үзеннән дә ишетергә тели. Хәзрәти Йосыф исә әүвәлрәк сөйләгәннәрен кабатлый. Төшен шундый матур юрауга хәйран калган Мәлик нинди чара күрергә кирәклеген сорый.

Йосыф галәйһис-сәләәм җавабында: «Муллык елларында күп иген үстереп, амбарларга тутырырга кирәк. Шул рәвешле кытлык елларында үзегезнең тормыш-көнкүрешегезне дә тәэмин итәрсез, чит төбәкләргә сатып, казнага да керем китерерсез», – дип аңлата.

Бу юлы Мәлик: «Ярый, ә бу эшне кем башкарачак соң?» – дип сорый, Хәзрәти Йосыф:

قَالَ اجْعَلْنِي عَلَى خَزَآئِنِ الْأَرْضِ إِنِّي حَفِيظٌ عَلِيمٌ

**«”Мине бу җирнең хәзинәләренә билгелә. Һичшиксез, мин – (аларны) саклаучы һәм (бу эшләрне) белгән кешемен”, – диде»** («Юсуф», 55).

Әлеге аятьтән аңлашылганча, гаделлек һәм дин хөкемнәрен сакларга һәм үтәргә көче җиткән затның җитәкчелек вазифасын соравы рөхсәт ителә. Ләкин мөселманнарның үз араларында мондый теләк белән йөрүе, андый урын таләп итүе хупланмый.

Әбү Муса әл-Әшгарый радыйаллаһу ганһе болай дип тапшыра:

Агамның уллары ның икесе белән Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына кергән идем. Алардан берсе: «Йә, Рәсүлүллаһ! Җәнабел-Хак Сиңа биргән җитәкчелек вазифаларының берсенә безне әмир итеп куй!» – диде. Агамның икенче улы да шуңа охшашрак сүзләр әйтте.

Боларга җавап итеп, Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Валлаһи, без үзе сорап алганны яки карьерачылык, дәрәҗәгә кызыгу сыйфаты булган затны идарәче итеп куймыйбыз»*, – диде (Бохари, «Ахкам», 7; Мөслим, «Имарә», 15).

Бу хәдис-шәрифтән аңлашылганча, теге яки бу вазифага билгели торган дәрәҗәгә ия шәхесләр җаваплы эшне һичшиксез аңа туры килгән затны куярга, вазифага ниятләгән кешеләрнең шәхси теләгенә, соравына түгел, ул эшкә лаеклымы-түгелме икәнлегенә игътибар итәргә тиеш.

Йосыф галәйһис-сәләәмнең җитәкче вазифага теләген белдергән югарыдагы аяти кәримә, шул ук вакытта Аллаһның әмерен өстен чыгарып, батыйльны куу, Хак Тәгаләне барлык кодрәт һәм бөеклеге белән күрсәтү өчен башка чара калмаган заманнарда, идарәне кяфер зат яки залим солтан кулыннан алуныңваҗиблегенә дә дәлил булып тора. Ләкин бу вазифа гаять авыр, җаваплылыгы да бик зур. Димәк, ул эшнең аңа лаеклылар тарафыннан башкарылуы зарур. Йосыф галәйһис-сәләәм дә бу мәсьәләдәге барлык сыйфатларга иң югары дәрәҗәдә ия булганга күрә, дөньяны төзәтү, яхшырту максатын күздә тотып, вазгыятьнең шулай таләп итүе сәбәпле, финанслар белән идарә эшен үз кулына ала.

Җәнабел-Хак болай ди:

وَكَذَلِكَ مَكَّنَّا لِيُوسُفَ فِي الْأَرْضِ يَتَبَوَّأُ مِنْهَا حَيْثُ يَشَاءُ نُصِيبُ بِرَحْمَتِنَا مَنْ نَشَاءُ
وَلَا نُضِيعُ أَجْرَ الْمُحْسِنِينَ. وَلَأَجْرُ الْآخِرَةِ خَيْرٌ لِلَّذِينَ آمَنُوا وَكَانُوا يَتَّقُونَ

**«Теләгән җирендә урнаша алсын өчен, Без Йосыфка ул туфракта мөмкинлек (кодрәт һәм хөрмәт) бирдек. Без рәхмәтебезне теләгәнебезгә ирештерәбез. Һәм Без игелек иясе колларыбызның әҗерен юк итмибез. Ахирәт әҗере иман китерүчеләр һәм тәкъвалык ияләре (яманлыклардан тыелганнар) өчен яхшырак»** («Юсуф», 56–57).

Үзенең бар сәләт-осталыгын кулланырга рөхсәт итеп, Мәлик бөтен Мисыр белән идарә эшен тулысынча Йосыф галәйһис-сәләәмгә тапшыра. Пәйгамбәргә күрсәткән шундый хөрмәт һәм илтифат нәтиҗәсендә булса кирәк, Аллаһның рәхмәте белән Мәлик Йосыф галәйһис-сәләәм каршында иман китерә. Аның белән бергә тагын бер төркем кешеләр дә иманга килә. Чөнки Йосыф галәйһис-сәләәм бу халыкка Пәйгамбәр итеп җибәрелгән була һәм аларны тәүхидкә өнди.

Шуны белергә кирәк: башкаларга бирергә, бүлешергә әзер булу – мәңгелек бәхеткә бер нигез тәшкил итә. Мондый игелекле эшләр кяфер тарафыннан кылынса, мөэмин зат, аның күңелендәге йомшаклык һәм юмартлык сыйфатыннан файдаланып, андый вакытларда ул кяферне иман һәм тәүхидкә чакыру мөмкинлеген кулдан ычкындырмаска тиеш. Чөнки шул нигездә ул кяфернең илаһи газаптан котылачагына өмет ителә.

Мисыр белән идарә итү үзенә тапшырылгач, Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм, вазифасына керешер-керешмәс, авыл хуҗалыгына, игенчелеккә игътибар юнәлтә. Җитештерүне арттырып, ихтыяҗлардан артып калганны, амбарларга туплаттыра. Кытлык еллары килгәч, амбарлардагы ашлыкны үз дәүләтенең ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен куллана, чит илләргә озатып, казнаны да баета. Кешеләр төрле төбәкләрдән килеп, Йосыф галәйһис-сәләәмнән азык-төлек сатып ала башлый.

**Зөләйха белән өйләнешүе**

Бу вакытларда Зөләйха, бар мал-мөлкәтен таратып, һичнәрсәсез калган була. Йосыфка тоткан гыйшкы сәбәпле күзләре кибә, гәүдәсе бөкрәя. Тәмам карчыкка охшап кала. Ахырда исә Йосыф үтә торган юлдагы бер җимерек йортка урнаша. Башыннан узган вакыйгаларны уйлап, хакыйкатьне аңлый һәм үзе табына торган пот каршына килеп: «Ни үкенеч сиңа һәм сиңа табынучыга! Шушы картлыгыма, сукырлыгыма һәм фәкыйрьлегемә карата да мәрхәмәтле булмадың! Бүгеннән башлап сине инкяр итәм һәм Йосыфның Раббысына иман китерәм», – ди. Шул рәвешле һидәяткә ирешеп, Зөләйха иртә-кич Аллаһны зикер кыла башлый.

Беркөнне Йосыф галәйһис-сәләәм атка атланып, яраннары, ярдәмчеләре белән бергә, Зөләйханың өе янынннан узып бара. Зөләйха шундук өеннән чыга һәм Йосыфның юлы тирәсендә: «Шул Кодрәт Иясен мактыйм ки, ул солтаннарны гөнаһлар аркасында колга әйләндерер; колларны исә Хак Тәгаләгә гыйбадәтләре өчен солтан итеп күтәрә!..» – дип кычкырып тәкрарлый.[105]

Аллаһның әмере белән җил бу тавышны Йосыфның колагына алып килә. Йосыф, Зөләйханы танымыйча, аның хәлен сораша. Зөләйха, үзен бары Йосыф кына дәвалый алачагын әйтеп, аның каршына чыга. Йосыф галәйһис-сәләәмнән ул әүвәлге чибәрлеген һәм күрер күзләренең кире кайтарылуын сорап дога кылуын, аннары исә үзен хатынлыкка алуын үтенә.

Йосыф галәйһис-сәләәм аның беренче ике теләген үти һәм, Аллаһның рөхсәте белән, Зөләйханың күзләре күрә башлый, элекке чибәрлеге кире кайта. Фәкать өченче үтенечкә килгәндә, Йосыф галәйһис-сәләәм, башын аска иеп, тирән уйга чума. Шулвакыт Җәбраил галәйһис-сәләәм килә һәм Хәзрәти Йосыфка: «И, Йосыф! Раббың Сиңа сәлам юллый һәм ул хатынның үтенечен кире какмаска куша! Аның белән никахлаш, чөнки ул – дөньяда һәм ахирәттә Синең хатының!»

Бу әмерне алгач, Йосыф галәйһис-сәләәм Зөләйханы үзенә хатынлыкка ала. Соңыннан Йосыф галәйһис-сәләәм, кулларын күккә ачып, болай дип дога кыла:

«И, миңа шулкадәр нигъмәтләр бирүче, мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе булган Аллаһым! Сиңа сансыз хәмед-сәнәләр булсын! Илаһи! Миңа насыйп нигъмәтләрне тәмам бирүеңне, миңа атам Ягъкубның йөзен күрсәтүеңне, мине дә аңа күрсәтеп, аның да күзләрен нурландыруыңны, кардәшләремә дә минем белән көрәшү юлларын ачуыңны Синнән сорыйм, Раббым! Син доганы кабул итүче, Син һәрнәрсәгә кодрәтле!»

105. Карагыз: Сәййид Али Хәмәдани, «Заһиратүл-Мүлук», хәзерләүче – Нәҗдәт Йылмаз, Истанбул, 2003, 118–119 б.

## Туганнарының азык-төлеккә килүе һәм Хәзрәти Йосыфның күркәм планы

Ул чорда кытлык сәбәпле Ягъкуб галәйһис-сәләәм, Йосыфның бертуганы Бүньяминне үз янында калдырып, азык-төлек алып кайту өчен, башка улларын Мисырга җибәрә. Аяти кәримәләрдә бу вакыйга да искә алына:

وَجَاءَ إِخْوَةُ يُوسُفَ فَدَخَلُوا عَلَيْهِ فَعَرَفَهُمْ وَهُمْ لَهُ مُنْكِرُونَ. وَلَمَّا جَهَّزَهُمْ بِجَهَازِهِمْ قَالَ ائْتُونِي بِأَخٍ لَكُمْ مِنْ أَبِيكُمْ أَلَا تَرَوْنَ أَنِّي أُوفِي الْكَيْلَ وَأَنَا خَيْرُ الْمُنْزِلِينَ. فَإِنْ لَمْ تَأْتُونِي بِهِ فَلَا كَيْلَ لَكُمْ عِنْدِي وَلَا تَقْرَبُونِ.

**«Йосыфның кардәшләре килде һәм аның янына керделәр. Ул (Йосыф) аларны таныды, алар (кардәшләре) исә аны танымадылар. Ул (Йосыф) аларны ихтыяҗлары белән тәэмин иткәч, әйтте: “Атагыз бер булган энегезне миңа китерегез. Күрмисезме, һичшиксез, мин бит үлчәүне тутырам, һәм мин – кунак хөрмәтләүчеләрнең иң яхшысымын. Әмма әгәр аны миңа алып килмәсәгез, артык сезгә минем янымда үлчәнәчәк бер ризык юк, хәтта миңа якынлашмагыз да!”»** («Юсуф», 58–60).

Йосыф галәйһис-сәләәмнең Мисырга килмәгән туганы турында сүз кузгатуының анык сәбәбе дә бар: кытлык сәбәпле, азык-төлек ихтыяҗга карап бирелә. Ә моның өчен исә ярдәм сыйфатында бирелә торган ризыкны алачак кешенең шәхсән булуы таләп ителә. Хәзрәти Йосыфның туганнары килә алмаган әтиләре һәм энеләре өчен дә бирәр өлеш сорагач, Йосыф галәйһис-сәләәм, карт атасының гафу ителергә лаеклы сылтавы бар дип санап, бер өлеш ризык бирә. Ләкин башка вакытта икенче туганының да килүен шарт итеп куя. Шул ысул белән ул туганын күрергә һәм аннан хәбәр алырга тели. Туганнары:

قَالُوا سَنُرَاوِدُ عَنْهُ أَبَاهُ وَإِنَّا لَفَاعِلُونَ. وَقَالَ لِفِتْيَانِهِ اجْعَلُوا بِضَاعَتَهُمْ فِي رِحَالِهِمْ لَعَلَّهُمْ يَعْرِفُونَهَا إِذَا انْقَلَبُوا إِلَى أَهْلِهِمْ لَعَلَّهُمْ يَرْجِعُونَ. فَلَمَّا رَجَعُوا إِلَى أَبِيهِمْ قَالُوا يَا أَبَانَا مُنِعَ مِنَّا الْكَيْلُ فَأَرْسِلْ مَعَنَا أَخَانَا نَكْتَلْ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ. قَالَ هَلْ آمَنُكُمْ عَلَيْهِ إِلَّا كَمَا أَمِنْتُكُمْ عَلَى أَخِيهِ مِنْ قَبْلُ فَاللَّهُ خَيْرٌ حَافِظًا وَهُوَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ

**«Әйттеләр: “Без аны хәйлә белән атасыннан сораячакбыз. Һәм, һичшиксез, без – үтәрлек кешеләрбез”. (Йосыф) хезмәтчеләренә әйтте: “Акчаларын йөкләре эченә куегыз, бәлки, алар гаиләләренә кайткач, моны аңларлар һәм, бәлки, (монда кире) кайтырлар”. Аталары янына кайткач: “И, әтиебез! Безгә артык ризык үлчәмәячәкләр (ризык алу тыелды). Безнең белән бергә энебезне дә (Бүньяминне дә) җибәр һәм (аның ярдәмендә) үлчәү алыйк. Һичшиксез, без аны саклаячакбыз”, – диделәр.**

**Ул (Ягъкуб): “Аны сезгә, элек кардәшен дә ышанып биргәнем кебек, ышанып биримме? (Мин аны бары Аллаһка гына әманәт итәм) Аллаһ, саклаучы буларак, яхшырак. Ул – мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе”, – диде»** («Юсуф», 61–64).

Ягъкуб галәйһис-сәләәм: «Аллаһ, саклаучы буларак, яхшырак. Ул – мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе», – дигәч, Аллаһ Тәгалә: «Гыйззәтем һәм бөеклегем хакына син Миңа шушы рәвешле буйсынасың, тәвәккәл кыласың, Мин исә Сине ике улың белән берьюлы кавыштырачакмын!» – дип белдерә.

Моннан мөэминнең фани нәрсәләргә түгел, Аллаһка таянырга, эш-гамәлне һәрвакыт Аңа багышларга, Аңа тәвәккәл кылырга тиешлеге аңлашыла. Чөнки Аллаһтан башка һәрнәрсә беренче чиратта үзе яклауга мохтаҗ. Аллаһ Тәгалә исә һичнәрсәгә мохтаҗ түгел. Ләкин Аллаһка тәвәккәл кылганда, эшне аңа тапшырганда да, сәбәп-шартларның үтәлешен кире какмау таләп ителә.

Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең уллары, Бүньяминне үзләре белән алып барып, Мисырдан азык-төлек алып кайту мөмкинлеге өчен, аталарын төрлечә юмалыйлар, аны ризалатырга тырышалар:

وَلَمَّا فَتَحُوا مَتَاعَهُمْ وَجَدُوا بِضَاعَتَهُمْ رُدَّتْ إِلَيْهِمْ قَالُوا يَا أَبَانَا مَا نَبْغِي هٰذِهِ بِضَاعَتُنَا
رُدَّتْ إِلَيْنَا وَنَمِيرُ أَهْلَنَا وَنَحْفَظُ أَخَانَا وَنَزْدَادُ كَيْلَ بَعِيرٍ ذٰلِكَ كَيْلٌ يَسِيرٌ

**«Әйберләрен ачкач, акчаларын үзләренә кире бирелгәнен күрделәр һәм: “И, әтиебез! Без нәрсә тели алабыз? Менә безгә кире бирелгән акчабыз. Гаиләбезгә (шуның белән кабат) азык-төлек алып кайтырбыз, энебезне дә сакларбыз һәм бер дөя йөге үлчәмендә артык ризык алырбыз. Бу (алганнарыбыз) исә бик аз бер үлчәм”, – диделәр»** («Юсуф», 65).

Ахырда Хәзрәти Ягъкуб Бүньяминне җибәрергә ризалаша.

قَالَ لَنْ أُرْسِلَهُ مَعَكُمْ حَتَّى تُؤْتُونِ مَوْثِقًا مِنَ اللّٰهِ لَتَأْتُنَّنِي بِهِ إِلَّا أَنْ
يُحَاطَ بِكُمْ فَلَمَّا آتَوْهُ مَوْثِقَهُمْ قَالَ اللّٰهُ عَلَى مَا نَقُولُ وَكِيلٌ. وَقَالَ يَا بَنِيَّ لَا تَدْخُلُوا
مِنْ بَابٍ وَاحِدٍ وَادْخُلُوا مِنْ أَبْوَابٍ مُتَفَرِّقَةٍ وَمَا أُغْنِي عَنْكُمْ مِنَ اللّٰهِ مِنْ شَيْءٍ إِنِ
الْحُكْمُ إِلَّا لِلّٰهِ عَلَيْهِ تَوَكَّلْتُ وَعَلَيْهِ فَلْيَتَوَكَّلِ الْمُتَوَكِّلُونَ

**«Ул: “Сез камалышка (чарасыз хәлдә) калмасагыз гына, аны миңа тулысынча алып кайтачагыгыз хакында Аллаһ белән ант итмичә, аны сезнең белән бергә җибәрмәячәкмен”, – диде. Алар аңа (ул теләгәнчә) ант иткәч, ул: “Без сөйләгән бу нәрсәгә Аллаһ – Яклаучы (шаһит)”, – диде. (Аннары) ул: “И, улларым! (шәһәргә) бер генә капкадан кермәгез, аерым-аерым капкалардан керегез. Мин Аллаһтан (киләчәк) һичбер**

**нәрсәне дә (бәла-казаны) сездән ерагайта алмыйм. Хөкем – Аллаһта гына. Мин Аңа гына тәвәккәл иттем. Тәвәккәл итүчеләр исә Аңа гына тәвәккәл итсен", – диде»** («Юсуф», 66–67).

Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең улларына нәсыйхәтендә Мисырга төрле капкалардан керергә кушуы аларның матур килеш-килбәтле, яхшы киемле булуы, өстәвенә әүвәлге сәфәрләрендә Мәлик тарафыннан башка берәү дә күрмәгән сый-хөрмәт күрсәтелүе белән бәйле. Шул сәбәпле, Ягъкуб галәйһис-сәләәм, улларының яман ниятле кешеләр, юлбасарлар тозагына эләгеп, зыян күрүен теләми. Өстәвенә, һәркемнең аптыраган карашлары аларга төбәлгән була. Шәһәргә бергәләп кергән очракта, башларына бәла алырга мөмкиннәр.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез болай дигән:

*«Күз тию – хак нәрсә»* (Бохари, «Тыйб», 36);

*«Күз тию кешене – кабергә, дөяне казанга кертер (үтерер)»* (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 60).

Шунлыктан һичкайчан ваемсызлык белән, Аллаһны онытып карарга ярамый, чөнки күз тияргә мөмкин. Даими рәвештә Аллаһка сыгынмаган бәндәләр начар күз тиюдән котылып кала алмый. Һәр очракта да Хак Тәгаләгә сыенучылар исә сакланган-якланган булыр.

Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмәдән мондый риваять тапшырылган:

«Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Хәсән белән Хөсәенне сакласын өчен, Аллаһка түбәндәге доганы укып сыгына:

أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللّٰهِ التَّامَّةِ مِنْ كُلِّ شَيْطَانٍ وَهَامَّةٍ وَمِنْ كُلِّ عَيْنٍ لاَمَّةٍ

*"Һәртөрле шайтаннан, (елан-чаян кебек) агулы хайваннардан һәм начар күз тиюдән Аллаһның мөкәммәл кәлимәләренә (Коръән аятьләренә, Аллаһның исем-сыйфатларына) сыгынам".*

Аннары*: "Атагыз Ибраһим дә, (уллары) Исмәгыйль белән Исхак өчен шушы дога ярдәмендә Аллаһка сыгына иде", – дип әйтә»* (Бохари, «Әнбия», 10; Әбү Давыт, «Сөннәт», 20).

Күңеленә хуш килгән берәр нәрсәгә күзе тиеп, зыян салмас өчен, кеше:

مَا شَاءَ اللّٰهُ لَا قُوَّةَ اِلاَّ بِاللّٰهِ

«Аллаһның теләгәне чынга ашар, көч-куәт бары Аллаһка гына хас», – дип;

Ул нәрсә күбәйсен, бәхетле һәм бәрәкәтле булсын өчен:

بَارَكَ اللّٰهُ فِيكَ وَعَلَيْكَ

«Аллаһ моны хәерле кылсын!» – дип әйтергә тиеш.

Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең бу киңәш-нәсыйхәтләрен тыңлагач, уллары, кабат ризык эзләп, юлга кузгала. Аяти кәримәдә болай диелә:

وَلَمَّا دَخَلُوا مِنْ حَيْثُ أَمَرَهُمْ أَبُوهُمْ مَا كَانَ يُغْنِي عَنْهُمْ مِنَ اللَّهِ مِنْ شَيْءٍ إِلَّا حَاجَةً فِي نَفْسِ يَعْقُوبَ قَضِيهَا وَإِنَّهُ لَذُو عِلْمٍ لِمَا عَلَّمْنَاهُ وَلَكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ

**«Алар аталары кушкан урыннан (төрле капкалардан) керделәр, әмма бу (чара) Аллаһтан бернәрсәне дә алардан ерагайтмады (файда китермәде), ләкин Ягъкубның күңеленнән бер теләк иде ки, ул аны үтәде. Без аңа өйрәткәнебез өчен, һичшиксез, ул гыйлем иясе иде (Шунлыктан "Аллаһтан киләчәк тәкъдирне үзгәртә алмам", дигән иде). Ләкин кешеләрнең күбесе (бу хакыйкатьне) белмиләр»** («Юсуф», 68).

**Синең кардәшең – Йосыф мин!**

وَلَمَّا دَخَلُوا عَلَى يُوسُفَ آوَى إِلَيْهِ أَخَاهُ قَالَ إِنِّي أَنَا أَخُوكَ فَلَا تَبْتَئِسْ بِمَا كَانُوا يَعْمَلُونَ

**«(Кардәшләре) Йосыфның хозурына кергәч, (Йосыф) кардәшен (Бүньяминне) үзенә кабул итте һәм: "Һичшиксез, мин – синең карендәшең. Аларның (әүвәлдә) кылган нәрсәләре сине борчымасын", – диде»** («Юсуф», 69).

Риваятькә күрә, Хәзрәти Йосыф туганнарына ризык тәкъдим итә. Аларны табынга икешәрләп утырта. Бүньямин, берүзе генә калгач: «Туганым Йосыф исән-сау булса, ул да минем белән бергә утырыр иде», – дип елап җибәрә.

Йосыф галәйһис-сәләәм исә аны үз өстәле янына чакыра. Сыйлагач, ул туганнарын янә парлап кунак бүлмәләренә озата. Бүньямин кабат берүзе генә кала. Шуннан соң Хәзрәти Йосыф: «Монысының пары юк! Алайса, ул минем белән калсын!» – дип боера. Шулай итеп Бүньямин аның янында төн куна.

Хәзрәти Йосыф аңа сүз ката: «Үлгән туганың урынына мине кардәш сыйфатында кабул итәрсеңме?» Бүньямин җавабында: «Синең кебек туганны каян табасың? Ләкин син әтием Ягъкуб белән әнием Рахил баласы түгел бит», – дигәч, Хәзрәти Йосыф елый башлый һәм, торып басып, Бүньяминны кочаклап ала. Шуннан соң хакыйкатьне сөйләп бирә: «Мин синең туганың Йосыф бит! Аларның кылган нәрсәләре сине борчымасын!»

Йосыф галәйһис-сәләәмнең Бүньямингә: «Аларның әүвәлдә кылган нәрсәләре сине борчымасын!» – дигән сүзләрендә Аллаһның көнчеләр кылган хәйлә-мәкернең уңышка ирештертмәячәгенә ишарә ясала. Чыннан да туганнары Йосыфка ни генә кылсалар да, аңардан ничек кенә көнләшсәләр дә, нинди

генә җәфалар күрсәтсәләр дә, ниятләренә ирешә алмыйлар. Аллаһ Тәгалә әүвәл ике бертуганны, аннары ата белән улны бер-берсе белән кавыштыра.

### Хәзрәти Йосыфның Бүньяминне алып калуы

Үзенең кем икәнен туганы Бүньяминга белдергәч, Йосыф аңа болай дип әйтеп куя: «И туганым! Мин сине үз янымда алап калачакмын. Беләсең бит, минем белән аерылышуы аркасында әтием бик кайгы-сагышка чумды. Әгәр сине дә монда алып калсам, тагын да ныграк кайгырачак. Әмма бераз соңрак аның белән кавыша алыр өчен, нәкъ менә шулай эшләвебез зарур. Мин моның өчен бик шәп бер план корырмын». Бүньяминга бу хакта әйткәннән соң:

فَلَمَّا جَهَّزَهُم بِجَهَازِهِمْ جَعَلَ السِّقَايَةَ فِي رَحْلِ أَخِيهِ ثُمَّ أَذَّنَ مُؤَذِّنٌ أَيَّتُهَا الْعِيرُ إِنَّكُمْ لَسَارِقُونَ. قَالُوا وَأَقْبَلُوا عَلَيْهِم مَاذَا تَفْقِدُونَ. قَالُوا نَفْقِدُ صُوَاعَ الْمَلِكِ وَلِمَنْ جَاءَ بِهِ حِمْلُ بَعِيرٍ وَأَنَا بِهِ زَعِيمٌ. قَالُوا تَاللَّهِ لَقَدْ عَلِمْتُمْ مَا جِئْنَا لِنُفْسِدَ فِي الْأَرْضِ وَمَا كُنَّا سَارِقِينَ. قَالُوا فَمَا جَزَآؤُهُ إِنْ كُنْتُمْ كَاذِبِينَ. قَالُوا جَزَآؤُهُ مَنْ وُجِدَ فِي رَحْلِهِ فَهُوَ جَزَاؤُهُ كَذَلِكَ نَجْزِي الظَّالِمِينَ

**«Ул аларның ихтыяҗларын тәэмин иткәч, су савытын кардәшенең йөге эченә куйды. Шуннан соң (кәрван кузгалгач), бер сөрәнчесе: “Әй, кәрван! Сез – караклар (урлашкансыз)!” – дип кычкырды. Алар (Йосыфның кардәшләре) ул кешеләргә борылдылар һәм: “Нәрсә югалттыгыз?” – диделәр. Алар (җаваплы затларның берсе) әйттеләр: “Без хөкемдарның су үлчәвен (савытын) таба алмыйбыз. Аны табып китерүчегә бер дөя йөге (бүләк бар). (Болар арасыннан) мин – моның өчен җаваплы”. Алар: “Аллаһ белән ант итәбез, сез беләсез бит, без бу җиргә фетнә чыгарыр өчен килмәдек һәм без – караклар түгелбез”, – диделәр. “Әгәр сез ялганчы булсагыз, моның җәзасы нәрсә?” – диделәр. Алар: “Ул кемнең йөгендә табылса, шул кешенең үзе – аның җәзасы (ягъни урлашу сәбәпле ул кулга алыныр һәм хөкем ителер). Без золым эшләүчеләрне (каракларны) шулай җәзага дучар итәбез”, – диделәр»** («Юсуф», 70–75).

Ягъкуб галәйһис-сәләам шәригатендә карак, тотылгач, үзе урлаган мал хакын кайтарыр өчен, аның хуҗасына бер ел кол булып хезмәт итәргә тиеш. Мисыр кануннарында исә каракка таяк белән сугалар һәм аннан урланган мал хакын икеләтә түләттерәләр. Хәзрәти Йосыф та бертуганы Бүньяминне үз янында калдыру өчен, аталарының шәригатенә күрә җәза бирдертергә тели һәм шуңа күрә нинди җәза тиешлеге турында туганнарыннан сорый.

Аяти кәримәдә болай диелә:

فَبَدَأَ بِأَوْعِيَتِهِمْ قَبْلَ وِعَاءِ أَخِيهِ ثُمَّ اسْتَخْرَجَهَا مِنْ وِعَاءِ أَخِيهِ كَذَلِكَ كِدْنَا لِيُوسُفَ مَا كَانَ لِيَأْخُذَ أَخَاهُ فِي دِينِ الْمَلِكِ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللَّهُ نَرْفَعُ دَرَجَاتٍ مَنْ نَشَاءُ وَفَوْقَ كُلِّ ذِي عِلْمٍ عَلِيمٌ.

**«Карендәшенең савытыннан алда аларның (башкаларның) савытларыннан башлады, һәм соңыннан аны кардәшенең савытыннан чыгарды. Без Йосыфка (кардәшен алып калу өчен) мондый бер чара өйрәттек. Аллаһ теләмәгән булса, ул мәликнең хөкеменә күрә карендәшен калдыра алмаячак иде. Без теләгәнебезне өстен дәрәҗәләргә күтәрәбез. Һәр гыйлем иясенең өстендә тагын да яхшырак белгән берәү бар»** («Юсуф», 76).

Йосыф галәйһис-сәләәм, туганы Бүньяминне үз янында алып калу өчен, Аллаһның кушуы буенча, зирәклек үрнәге булган бер матур план кора. Риваятьтә әйтелгәнчә, бу планын кардәшенә сөйләп, аның белән дә килештерә.

Йосыф галәйһис-сәләәм бу гамәле белән туганнарыннан үч алу максатын күздә тотмый, чөнки үзенә кылган золымны гафу итә. Ләкин туганнары кылган эшләрдә Аллаһ хакы да була, аларын ярлыкау Йосыфның кулында түгел. Ул бары туганнарының Аллаһ каршында ярлыкауга лаек булуларын гына сорый. Шунлыктан, үзенең кем икәнен белдергәнче, Аллаһ хакына бәйле кисәтүгә ишарәләгән «сез, һичшиксез, карак!» дигән гаепләү белән туганнарында ихлас үкенеч хисе уятырга тели. Алар кылган иң куркыныч караклык – хәйлә юлы белән Йосыфны аталарыннан урлап китү. Аларны бөтен эшләгән начарлыкларыннан тәүбәгә юнәлтер өчен, Йосыф галәйһис-сәләәм Бүньяминне шул рәвешле үз янында калдыра. Хактан да, аннан соңгы сәфәрләрендә туганнарының никадәр йомшак күңел, нинди саф-чиста уй-ниятләр белән килгәнлекләре күзгә ташлана.

Димәк, бу вакыйга күп кенә яшерен хикмәтләрне үз эченә алган илаһи җәза һәм тәрбия була. Икенче яктан караганда исә, үзенең кем икәнен белгертер вакыт җитмәгәнен белгән Йосыф галәйһис-сәләәм, туганын алып калу юллары турында уйлаганда да, көчләү, басым ясау ысулына мөрәҗәгать итми, үзенең дәрәҗәсеннән, вәкаләтеннән явызларча файдалануга бармый. Йосыф галәйһис-сәләәм золым һәм көч-басым куллануда гаепләрлек мөнәсәбәтләрдән, гамәлләрдән тыела, мәсьәләне бары гадел һәм канунлы юллар белән генә чишүгә ирешә.

Шул рәвешле Йосыф галәйһис-сәләәм бер үк вакытта атасы шәригатен Мисырда куллана башлауга да юл ачып җибәрә.

Аллаһ берәр нәрсәнең булуын максат итсә, моның сәбәпләрен дә хәзерләп куяр. Шуңа бер яктан Йосыфка туганнарының үзләреннән хөкем чыгарттыру ысулын өйрәтеп, икенче яктан кардәшләргә сиздерми генә, аларның үзләреннән җавап әйттереп, хөкем кылдыра. Шул рәвешле ул, дәүләт кануннарын бозмыйча, аларның авызын үз карарлары белән яба, шунда ук атасы шәри-

гатенең бер хөкемен куллану аша Мисырда урнашкан хокукый тәртипләргә гамәли, теп-тере бер үрнәк күрсәтә.

Йосыф галәйһис-сәләәм әлеге планы белән туганнарын һич чарасыз калдырып, аталарының «бары чарасыз калуыгыздан тыш» дигән сүзләренә туры килгән хәлгә төшерә һәм аларны аталарына ант итеп әйткән сүзләренең җаваплылыгыннан коткара (Әлмалылы, IV, 2894–2898).

Эзләнгән су савыты Бүньяминнең йөгеннән килеп чыккач:

قَالُوا إِنْ يَسْرِقْ فَقَدْ سَرَقَ أَخٌ لَهُ مِنْ قَبْلُ فَأَسَرَّهَا يُوسُفُ فِي نَفْسِهِ
وَلَمْ يُبْدِهَا لَهُمْ قَالَ أَنْتُمْ شَرٌّ مَكَانًا وَاللّٰهُ أَعْلَمُ بِمَا تَصِفُونَ

**«Алар: “Әгәр ул урлаган булса, элек аның бер кардәше дә урлаган иде”, – диделәр. Йосыф моны (бу сүз белән бәйле кайгысын) эчендә яшерде һәм аны аларга күрсәтмәде, тик (күңеленнән): “Сезнең хәл (чынлыкта) яманрак. Аллаһ уйдырма нәрсәләрегезне яхшырак белә”, – диде»** («Юсуф», 77).

Шулай итеп Йосыфның туганнары: «Юк, бу эштә һичшиксез бер ялгышлык булырга тиеш!» – дип, үзләрен дә, Бүньяминне дә гаепләүдән коткарыр өчен башка юл эзлисе урынга, ачу-нәфрәт хисенә бирелеп, Йосыф һәм аның кардәшенә карата тойган көнчелекләрен тагын бер тапкыр сиздерәләр.

Хәзрәти Йосыфка яла итеп ягылган караклык вакыйгасы турында төрле фикерләр бар:

а) Йосыфның әни ягыннан бабасы мәҗүси була. Хәзрәти Йосыфның әнисе, атасын потларга табынудан биздерү өмете белән, Йосыфка ул потларны урлап чыгып, ватарга куша. Йосыф исә кушылганча эшли;

б) Йосыф атасы табыныннан ризык алып, аны фәкыйрьләргә биргән. Әтисенең бер бәрәненме, тавыгынмы алып чыгып, ярлыларга биргәнлеге дә әйтелә;

в) Әтисенең сеңлесе Хәзрәти Йосыфны бик ярата. Ләкин Йосыф үскәч, атасы аны үз янына кайтарырга тели. Тик түтәсенең Йосыфтан бер дә аерыласы килми. Шуңа күрә Исхак галәйһис-сәләәмнән мирас булып калган путаны Йосыфның биленә бәйли дә, бу путаның югалуы турында сүз чыгара. Путаны эзли башлыйлар һәм Йосыфның өстендә табалар. Ул чор кануны таләбенчә, түтәсе Йосыфны үз янында алып кала;

г) Бу – яла гына, чөнки туганнарының күңелен, югарыда бәян ителгән вакыйгалардан соң күп еллар узуга карамастан, һаман да Йосыфка каршы үпкә-ачу биләп алган була. Йосыфны карак дип телгә алу вакыйгасы исә бер

тапкыр көнчелек авыруын эләктергән йөрәкнең ул көнчелек һәм нәфрәттән җиңел генә котыла алмаячагын күрсәтә (Разый, «Мәфатихул-Гайб», XVIII, 147).

Йосыфның караклыгы турында сүз «Сез – караклар!» дигән гаепләү аркасында борчылу тәэсирендә әйтелә һәм яшерен кимсетү булып тора.

Йосыфның кардәшләре:

قَالُوا يَا أَيُّهَا الْعَزِيزُ إِنَّ لَهُ أَبًا شَيْخًا كَبِيرًا فَخُذْ أَحَدَنَا مَكَانَهُ إِنَّا نَرَاكَ مِنَ الْمُحْسِنِينَ. قَالَ مَعَاذَ اللَّهِ أَنْ نَأْخُذَ إِلَّا مَنْ وَجَدْنَا مَتَاعَنَا عِنْدَهُ إِنَّآ إِذًا لَظَالِمُونَ

**«”И, хөкемдар! Анның бик карт атасы бар. Син анның урынына безнең беребезне ал. Без синең игелек кылган кешеләрдән булуыңны күрәбез”, – диделәр. Ул (Йосыф): ”(Без малыбызны кемдә тапсак, шуны алып калабыз). Әйберебезне тапкан кешедән башка берәүне алуыбыздан Аллаһка сыенабыз. Ул тәкъдирдә без залимнәрдән булыр идек”, – диде»** («Юсуф», 78–79).

Золым бик төрле була: Аллаһның хөкемнәренә каршы хөкем кылу да золым булган кебек, золымны теләп алу яки аңа ризалык күрсәтү дә – золымның нәкъ үзе ул. Артыгын кыланып, бәндә хакына керү башкаларга карата золым кылу санала, ахирәттә газап китерәчәк гөнаһлар эшләү исә кешенең үз нәфесенә золым кылуы булып тора.

Золымга яки ниндидер бәлагә тарыган зат, тәүбә вә истигъфар кылып, котылу чарасын Аллаһтан сорарга тиеш.

Сәһл ибне Габдуллаһ әт-Түстәри әйтә:

«Аллаһ, бер колын сөйгәндә, гөнаһын аның үзенә зур итеп күрсәтер һәм аңа тәүбә ишекләрен ачар. Бу ишекләр Аллаһка мәхәббәт бакчаларына илтә. Бер колга газап җибәрергә теләгәндә, Аллаһ аңа гөнаһларын кечерәйтеп күрсәтер һәм аңа төрле бәла-казалар белән сабак бирер. Чөнки гөнаһын вак итеп күргән зат үгет-нәсыйхәт кабул итмәс һәм кайгы-хәсрәткә таручылардан булыр».

Йосыфның туганнары башларына төшкән бу хәлләрдә нишләргә һәм аталарына ни дип әйтергә икәнен уйлый башлыйлар. Аяти кәримәдә аларның бу гамәле түбәндәгечә тасвирлана:

فَلَمَّا اسْتَيْأَسُوا مِنْهُ خَلَصُوا نَجِيًّا قَالَ كَبِيرُهُمْ أَلَمْ تَعْلَمُوا أَنَّ أَبَاكُمْ قَدْ أَخَذَ عَلَيْكُمْ مَوْثِقًا مِنَ اللَّهِ وَمِنْ قَبْلُ مَا فَرَّطْتُمْ فِي يُوسُفَ فَلَنْ أَبْرَحَ الْأَرْضَ حَتَّى يَأْذَنَ لِي أَبِي أَوْ يَحْكُمَ اللَّهُ لِي وَهُوَ خَيْرُ الْحَاكِمِينَ. ارْجِعُوا إِلَى أَبِيكُمْ فَقُولُوا

يَا أَبَانَا إِنَّ ابْنَكَ سَرَقَ وَمَا شَهِدْنَا إِلَّا بِمَا عَلِمْنَا وَمَا كُنَّا لِلْغَيْبِ حَافِظِينَ. وَاسْأَلِ الْقَرْيَةَ الَّتِي كُنَّا فِيهَا وَالْعِيرَ الَّتِي أَقْبَلْنَا فِيهَا وَإِنَّا لَصَادِقُونَ

**«Аннан (Бүньяминне коткарудан) өметләре өзелгәч, алар (пышылдашып) киңәшләшергә аерылдылар (читкәрәк киттеләр). Иң олылары әйтте: “Сез атабызның безне Аллаһ белән ант иттергәнен белмисезме әллә? Элегрәк тә Йосыф хакында гаделсезлек кылган идегез. Атам миңа рөхсәт бирми торып яки Аллаһ миңа хөкем бирми торып, мин бу җирдән, асылда, аерылмаячакмын. Һичшиксез, Ул – хөкем бирүчеләрнең иң яхшысы. Атагызга кайтыгыз да әйтегез: “И, әтиебез! Синең улың (без күрмәгәндә) урлады бит (су савытының аның йөгеннән табылганын үз күзләребез белән күрдек). Без белгәнебезгә генә шаһитлык итәбез, гаибне белмибез. (Ышанмасаң), без булган шәһәрдән һәм без кайткан кәрваннан (анда булган кешеләрдән) сора. (Бөтен ихласлыгыбыз белән әйтәбез): һичшиксез, без дөресен әйтәбез”»** («Юсуф», 80–82).

Кардәшләр юлга чыгып, аталары янына кайта һәм нәкъ өлкән абыйлары әйткән сүзне җиткерә.

### Әҗер-савап ишекләрен ачкан җәфалар

قَالَ بَلْ سَوَّلَتْ لَكُمْ أَنْفُسُكُمْ أَمْرًا فَصَبْرٌ جَمِيلٌ عَسَى اللَّهُ أَنْ يَأْتِيَنِي بِهِمْ جَمِيعًا إِنَّهُ هُوَ الْعَلِيمُ الْحَكِيمُ

**«(Аталары Ягъкуб): “Әйе, (шуннан янә куркам): нәфесләрегез сезгә бер эшне бизәгән (аякларыгызны тайдырган). (Миңа йөкләнгәне, бу хәл каршында тынычлык һәм өмет белән) күркәм сабырлык. Бәлки, Аллаһ миңа аларның барысын берьюлы кайтарыр. Һичшиксез, Ул – Белүче, Хикмәт иясе”, – диде»** («Юсуф», 83).

Йосыфның туганнары элегрәк аталарына ялган сөйләгәнлектән, Ягъкуб бу юлы әйткән хак сүзгә ышанасы килми һәм аларга: «Юк, нәфесләрегез, алдап, сезне шундый зур эшкә котырткан, югыйсә шәригатебездә каракның әсир итеп кулга алыначагын Мисыр патшасы каян белә алыр иде?» – дип әйтә.

وَتَوَلَّى عَنْهُمْ وَقَالَ يَا أَسَفَى عَلَى يُوسُفَ وَابْيَضَّتْ عَيْنَاهُ مِنَ الْحُزْنِ فَهُوَ كَظِيمٌ

**«Ул алардан йөз чөерде һәм: “Аһ, Йосыф өчен булган хәсрәтем!” – диде. Хәсрәтеннән ике күзенә дә ак төште. Ул хәсрәтен тыеп торды»** («Юсуф», 84).

Йосыфны югалткан көннән бирле Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең күзенә йокы әсәре керми. Ул заманда җир йөзендәге җан ияләренең Аллаһ каршында

иң шәрәфлесе Ягъкуб галәйһис-сәләәм була. Ахыр чиктә, елый-елый, Ягъкубның күзләренә ак төшә. Бу хәлнең бер хикмәте башка улларын күреп, кайгы-хәсрәте тагын да көчәеп китмәсен өчен булганлыгы да әйтелә.

Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

*«Аллаһ Тәгалә Хәзрәтләре: “Мин кемнең иң кыйммәтле ике нәрсәсен (күзләрен) алган булсам һәм ул зат савап өмет итеп сабырлык кылса, аңа җәннәттән кала башка әҗер-савап бирүгә риза булмам”, – дип белдерде»* (Тирмизи, «Зүһд», 58/2400).

Бохаринең риваяте исә мондый: *«Аллаһ Тәгалә Хәзрәтләре әйтте: “Мин колымны ул яраткан ике нәрсә белән сынасам, ул бу хәлдә сабырлык күрсәтсә (һәм савап өмет итсә), моңа җавап итеп җәннәтне бирермен”»* (Бохари, «Мәрда», 7).

Ягъкуб галәйһис-сәләәм кырык ел елый. Аның сукырлыгы турында кайбер мәшһүр шәхесләр мондый фикер белдерә:

Аллаһ Тәгалә Ягъкубка бу сукырлыкны Йосыфның тышкы кыяфәтен түгел, ә анда чагылыш тапкан «эчке гүзәллек»не даими күрә алсын өчен биргән. Чөнки Җәнабел-Хакның гүзәллек нурлары Йосыфта чагылыш тапкан һәм Ягъкуб та шуңа күрә Йосыфны артык яраткан була. Ләкин «Хөсни мотлак» (бәхәссез матур) булган Аллаһ Тәгаләгә каршы ихтыярсыз хата кылуы сәбәпле, Җәнабел-Хак Йосыфны атасыннан аера һәм Ягъкубны Йосыфның тышкы кыяфәтен күзәткән күзләреннән мәхрүм итә.

Монда шуңа ишарә ясала: бәндә галәмнең тышкы күренешләренә карый торган күздән һәм шул күргәннәреннән арынмый торып, «Хөсни мотлак» иясен, Илаһи гүзәллекне күзәтүгә ирешә алмас!

**Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзелмәс**

قَالُوا تَاللَّهِ تَفْتَؤُا تَذْكُرُ يُوسُفَ حَتَّى تَكُونَ حَرَضًا أَوْ تَكُونَ مِنَ الْهَالِكِينَ. 
قَالَ إِنَّمَا أَشْكُوا بَثِّي وَحُزْنِي إِلَى اللَّهِ وَأَعْلَمُ مِنَ اللَّهِ مَا لَا تَعْلَمُونَ

**«(Уллары, Хәзрәти Ягъкубка болай) диделәр: “(Гомерең узып китте) Алар: “Аллаһ белән ант итәбез, син гел Йосыфны искә аласың. Ахыр чиктә я (кайгыдан) хаста булачаксың, йә һәлак булачаксың”, – диделәр». Ул (Хәзрәти Ягъкуб) әйтте: «Мин хәсрәтемне һәм борчуымны Аллаһка гына шикаять итәм. Һәм мин сез белмәгән нәрсәләрне Аллаһтан (вәхи аша) беләмен»** («Юсуф», 85–86).

يَا بَنِيَّ اذْهَبُوا فَتَحَسَّسُوا مِنْ يُوسُفَ وَأَخِيهِ وَلَا تَيْأَسُوا مِنْ 
رَوْحِ اللَّهِ إِنَّهُ لَا يَيْأَسُ مِنْ رَوْحِ اللَّهِ إِلَّا الْقَوْمُ الْكَافِرُونَ

**«И, улларым! Барыгыз, Йосыф һәм аның карендәше турында сорашып белегез. Аллаһның рәхмәтеннән өметне өзмәгез. Һичшиксез, кяферләр кавеме генә Аллаһның рәхмәтеннән өметен өзә!»** («Юсуф», 87).

Әлеге аяти кәримәнең безгә җиткерергә теләгән хәбәре бик мөһим. Шунлыктан кол нинди хәлгә генә төшсә дә, паникага бирелмәскә һәм һәрвакыт Аллаһка өметләнергә тиеш. Чөнки аятьтә әйтелгәнчә, кяферләр генә Аллаһтан өмет өзәләр.

Хәдис-шәрифтә дә: *«Җәнабел-Хактан өмет өзмәгән гөнаһкяр Аллаһтан өмет өзгән гыйбадәт иясенә караганда Раббыга якынрак!»* – дип әйтелә (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 68).

Моның сәбәбе – Аллаһтан өмет өзү – Җәнабел-Хакның «Рахман һәм Рәхим» сыйфатларын аңламау, илаһи мәрхәмәтне танымау дигән сүз. Хәлбуки, хәтта Фиргавен дә соңгы сулышында Аллаһның исемен телгә ала.

Аллаһ Тәгалә башка бер аяти кәримәдә дә:

لَا تَقْنَطُوا مِنْ رَحْمَةِ اللّٰهِ

**«…Аллаһның рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез!..»** – дип боера («әз-Зүмәр», 53).

Әнә шул рәвешле Ягъкуб галәйһис-сәләәм дә, өметен өзмичә, Мисыр Газизенә, ягъни Йосыфка уллары аша хат җибәрә. Ягъкуб галәйһис-сәләәм бу чакта улы Йосыфның Мисыр Газизе икәнен белми. Хатта болай диелә:

«Бисмилләһир-рахманир-рахим!

Хәлилуллаһ Ибраһим улы Исхакның улы Исраил Ягъкубтан Мисыр Газизенә.

Без бик күп бәлаләргә дучар булган бер кавем. Бабаларымнан Ибраһим Нәмрудның утына атылды һәм сабыр итте. Аллаһ исә аны сау-сәламәт калдырды. Атам башка төрле кыенлыклар белән сыналды һәм сабыр итте. Аллаһ аңа да әҗерен бирде. Миңа килгәндә, мин исә улым Йосыфны югалттым. Аннан аерылу сагышыннан елый-елый, күзләрем күрмәс булды, билем бөгелде. Синең янда тотык булып тотылган улым белән үземне юата идем. Аның караклык кылуы турында әйткәнсең. Безнең нәселебездән булганнар урлашмас. Без караклар тудырмыйбыз. Аны миңа кайтарсаң, кайтарырсың, кайтармасаң, сиңа шундый бәддога укырмын ки, җиде буын балаларыңа тәэсире барыр!»[106]

Бу хатны алгач, Йосыф галәйһис-сәләәм елап җибәрә һәм мондый җавап яза:

«Бисмилләһир-рахманир-рахим!

106. Карагыз: «Рухул-Бәян», IV, 310.

Мисыр Газизеннән Исраил Ягъкубка.

И өлкән агай! Хатың килде. Укыдым һәм эчтәлеген аңладым. Анда изге ата-бабаларыңны искә алып, һәркайсының бәла-казаларга дучар булуы турында язасың. Алар кыенлыкларга ничек сабыр иткән булсалар, син дә шулай сабыр ит! Вәссәлам!»

Ягъкуб галәйһис-сәләәм бу җавапны алгач: «Аллаһ белән ант итәм, бу – патша хаты түгел, бер пәйгамбәр хаты. Моны язучы кеше Йосыф кына була ала», – дип, мәсьәләнең асылын белешсеннәр өчен, улларын кабат Мисырга җибәрә. Уллары шундук юлга кузгала:

فَلَمَّا دَخَلُوا عَلَيْهِ قَالُوا يَا أَيُّهَا الْعَزِيزُ مَسَّنَا وَأَهْلَنَا الضُّرُّ وَجِئْنَا
بِبِضَاعَةٍ مُزْجَيةٍ فَأَوْفِ لَنَا الْكَيْلَ وَتَصَدَّقْ عَلَيْنَآ إِنَّ اللّٰهَ يَجْزِي الْمُتَصَدِّقِينَ.
قَالَ هَلْ عَلِمْتُمْ مَا فَعَلْتُمْ بِيُوسُفَ وَأَخِيهِ إِذْ أَنْتُمْ جَاهِلُونَ

**«(Мисырга килеп), алар аның (Йосыфның) хозурына кергәч: “И, хөкемдар (Газиз)! Безгә дә, гаиләбезгә дә зарар (кытлык) кагылды. Без исә аз гына мал белән килдек. Син безгә үлчәүне тутырып бир һәм безгә мәрхәмәт күрсәт (сәдака бир). Һичшиксез, Аллаһ мәрхәмәт күрсәтүчеләрнең әҗерләрен бирәчәк”, – диделәр. Ул (Йосыф): “Сез надан кешеләр булган чакта, Йосыфка һәм аның кардәшенә ниләр эшләгәнегезне беләсез бит?” – диде»** («Юсуф», 88–89).

Тәфсирләрдә аңлатылганча, Хәзрәти Йосыфны коега ташлаган туганнары иң кече энеләре Бүньяминне дә гел кимсетеп, мыскыллап яшәгән була.

**Дастаннарда мактарлык гафу-кичерү**

قَالُوا ءَإِنَّكَ لَأَنْتَ يُوسُفُ قَالَ أَنَا يُوسُفُ وَهذَا أَخِي قَدْ مَنَّ اللّٰهُ عَلَيْنَا إِنَّهُ مَنْ
يَتَّقِ وَيِصْبِرْ فَإِنَّ اللّٰهَ لَا يُضِيعُ أَجْرَ الْمُحْسِنِينَ. قَالُوا تَاللّٰهِ لَقَدْ آثَرَكَ اللّٰهُ عَلَيْنَا وَإِنْ
كُنَّا لَخَاطِئِينَ. قَالَ لَا تَثْرِيبَ عَلَيْكُمُ الْيَوْمَ يَغْفِرُ اللّٰهُ لَكُمْ وَهُوَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ

**«Алар (кардәшләре): «Син, чыннан да, Йосыфмы әллә?» – диделәр. Ул: «(Әйе), мин – Йосыфмын, бу – минем кардәшем. Аллаһ безгә нигъмәт бирде. Һичшиксез, кем дә кем тәкъвалык иясе һәм (бәлаләргә) сабыр булса, Аллаһ игелек кылучыларның әҗерен юкка чыгармый», – диде.**

**Алар (кардәшләре): «Аллаһ белән ант итәбез, Аллаһ сине бездән артыграк күргән. Без исә (сезгә эшләгәннәребездә) гөнаһ кылган кешеләр булдык», – диделәр. Ул (Йосыф) әйтте: «Бүген сезгә бернинди шелтә дә,**

**(гаепләү дә) юк. Аллаһ сезне ярлыкасын. Ул бит – мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе»** («Юсуф», 90–92).

Әлеге аяти кәримәләр бер үк вакытта тәрбия ысулларының иң матурларыннан берсенә ишарәли. Сүз яманлыкка яхшылык белән җавап бирү турында бара. Чөнки мондый галиҗәнап мөнәсәбәт каршында хәтта дошман булганнарның да еш кына дошманлык хисләре бетә; дус та, дошман да булмыйча, урталык хәлендәгеләр дуслыкка авышыр; дусларның исә мәхәббәте көчәеп, тагын да якынаеп китәрләр.

Аяти кәримәдә бик матур әйтелә:

وَلا تَسْتَوِي الْحَسَنَةُ وَلَا السَّيِّئَةُ اِدْفَعْ بِالَّتِي هِيَ أَحْسَنُ
فَإِذَا الَّذِي بَيْنَكَ وَبَيْنَهُ عَدَاوَةٌ كَأَنَّهُ وَلِيٌّ حَمِيمٌ

**«Яхшылык белән явызлык тиң түгел. Син (яманлыкка) иң яхшы мөгамәлә белән (җавап) кайтар, шулвакыт сиңа дошман кеше гүяки шәфкатьле (самими) бер дус (булып куяр)!»** («Фуссыйләт», 34).

Бу мәсьәләдә Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән дә бер гыйбрәтле үрнәк китерик:

Галәмнәр горурлыгы булган Пәйгамбәребезнең агасының улы Әбү Суфьян ибне Харис, нәбилек вазифасы йөкләнгәнче, Рәсүлүллаһның дусты була. Пәйгамбәрлек килгәч исә, дошманга әйләнеп, Аңа карата мыскыллаулы, төртмәле шигырьләр яза. Пәйгамбәрнең шагыйре Хәсән ибне Сабит радыйаллаһу ганһе исә бу шигырьләргә җавап бирә. Соңыннан Әбү Суфьян ибне Харис бу гамәлләренә үкенә башлый. Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Мәккәне яулап алу өчен сәхабәләре белән сәфәргә кузгалганда, Әбү Суфьян ибне Харис Мәдинәи Мөнәввәрәгә таба юлга чыга. Юлда чакта Аллаһ Рәсүленә очрый. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әбү Суфьянның йөзенә карамый үтә. Әбү Суфьян моннан бик тәэсирләнә. Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе өйрәткән рәвештә: «Аллаһ белән ант итәм, чыннан да Аллаһ Сине бездән өстен итеп куйган. Хактан да, без (сезгә кылган эшләребез белән) хаталарга батканбыз», – аяте белән гафу үтенә.

Мәрхәмәт һәм шәфкать иясе булган Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә «Йосыф» сүрәсеннән: ***«Бүген сезгә бернинди шелтә дә, (гаепләү дә) юк. Аллаһ сезне ярлыкасын. Ул бит – мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе»***, мәгънәсендәге аяти кәримәне укып, Әбү Суфьян һәм башкаларның элекке хаталарын гафу итә.

Әбү Суфьян, мөселман булганнан соң, оялып, һичвакыт Пәйгамбәребезнең йөзенә күтәрелеп карый алмый (Вакыйди, «Мәгази», II, 810–811; Ибне Хишам, «Сыйрәт», IV, 20–24; Ибне Габделбәрр, «әл-Истигаб», IV, 1674).

Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән Рәсүл Әкрәм Әфәндебез, Мәккәне яулап, Кәгъбәгә аяк баскан чакта, корәешлеләр «әл-Хәрам» мәчетенә тула. Кәгъбә тирәсенә җыелып утырып, алар Пәйгамбәребезнең нишләячәген кызыксынып көтә.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Әй, корәеш халкы! Әй, мәккәлеләр! Ни дип әйтерсез? Хәзер мин сезне нишләтәчәк, дип уйлыйсыз?»* – дип сорый. Корәешлеләр: «Без Синең хәерлене һәм игелеклене кылачагың турында уйлыйбыз һәм: "Син хәерлене кылачаксың!"– дип әйтәбез. Син – киң күңеллеклек һәм игелеклелек сыйфатларына ия кардәш; киң күңеллелек һәм игелеклелек сыйфатларына ия кардәшнең улы! Көч-куәткә ия булдың, хәзер безгә карата яхшы мөгамәлә кыл!» – ди. Моңа җавап итеп, Пәйгамбәр Әфәндебез галәйһис-саләтү вәссәлам:

*«Минем хәлем белән сезнең хәлегез Йосыф галәйһис-сәләәм белән аның кардәшләренең вазгыяте кебек булачак. Йосыф кардәшләренә әйткән сыман, мин дә:* ***"Бүген сезгә бернинди шелтә дә, (гаепләү дә) юк. Аллаһ сезне ярлыкасын. Ул бит – мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе!"*** *– дим* («Юсуф», 92). *Барыгыз, сез азат һәм ирекле!»* – дип белдерә.

Аллаһ Тәгалә корәеш мөшрикләрен Рәсүленең хөкеменә бирә, аңа буйсындыра, ничә еллар мөэминнәргә китергән җәфаларының үчен алырлык кодрәт ирештерә, ә Рәхмәт Пәйгамбәре аларны шул рәвешле гафу итә һәм иректә калдыра. Шуңа күрә мәккәлеләргә «Туләка (азат ителгәннәр)» кушаматы тагыла (Ибне Хишам, «Сыйрәт», IV, 32; Вакыйди, «Мәгази», II, 835; Ибне Сәгъд, «Табакат», II, 142–143).

Бу вакыйга шул ук вакытта Җәнабел-Хакка хас «Саттарул-уюб», ягъни «гаепләрне каплаучы һәм хаталарны гафу итүче» сыйфатының бәндәдәге камил чагылышын да раслый.

Шагыйрь Зия Паша Йосыф галәйһис-сәләәм белән туганнары арасындагы әлеге вакыйганы шигырь юлларына сала:

«Залимнәргә беркөнне әйттерер Кодрәт иясе:

"Таллаһи ләкад асәракәллаһу галәйна"».[107]

### Күлмәгемне этиемнең күзләренә сөртегез

Йосыф галәйһис-сәләәм туганнарын иртәле-кичле сый белән кабул итә. Кардәшләре исә элек аңа карата кылганнарын хәтергә төшереп, әлеге сый-хөрмәте каршында бик кыенсыналар. Алар Хәзрәти Йосыфка бер кеше аша хәбәр җибәрәләр: «Син безне иртә-кич кунакка чакырасың! Ләкин без сиңа карата кылган эшләребез аркасында синнән оялабыз!» Йосыф галәйһис-сәләәм

107. «Аллаһ белән ант итәм, чыннан да Аллаһ Сине бездән өстен итеп куйган» («Юсуф», 91).

кардәшләренә мондый җавап юллый: «Мисырлылар хәзерге көнгә кадәр миңа беренче күргәндәй карыйлар һәм: «Егерме дирһәмгә сатылган бер колны шундый дәрәҗәгә күтәргән Аллаһны тәсбих итәбез!» – диләр. Хәзер исә сезнең аркада да хөрмәт казандым. Чөнки минем сезнең кардәшегез һәм Ибраһим галәйһис-сәләәм кебек олуг Пәйгамбәрнең оныгы икәнемне белделәр».

Йосыф галәйһис-сәләәм бу сүзләрне мактану өчен түгел, туганнарын юату, аларны тынычландыру, кыенсынуларын киметү өчен әйтә. Әлеге вакыйга аның кече күңеллелек һәм кичерә белүчәнлек сыйфатларының киңлеген раслый.

Туганнарын әнә шундый киң мәрхәмәтлелек белән гафу иткән Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм, атасының күзләре шифа тапсын өчен, аңа үзенең күлмәген җибәргәндә, кардәшләрен:

اِذْهَبُوا بِقَمِيصِي هَذَا فَأَلْقُوهُ عَلَى وَجْهِ أَبِي يَأْتِ بَصِيرًا وَأْتُونِي بِأَهْلِكُمْ أَجْمَعِينَ

**«Минем шушы күлмәгемне алып китегез һәм аны этиемнең йөзенә салыгыз, ул күрә башлар һәм (аннары) бөтен гаиләгез белән миңа килегез!»** – дип озата («Юсуф», 93).

وَلَمَّا فَصَلَتِ الْعِيرُ قَالَ أَبُوهُمْ إِنِّي لَأَجِدُ رِيحَ يُوسُفَ لَوْلَا
أَنْ تُفَنِّدُونِ. قَالُوا تَاللَّهِ إِنَّكَ لَفِي ضَلَالِكَ الْقَدِيمِ

**«Кәрван (күлмәкне алып кайту өчен Мисырдан) аерылган чакта, аталары: “Мин Йосыфның исен сизәм, мине акылы җиңеләйгән, димәсәгез”, – диде. Алар: “Аллаһ белән ант итәбез, син һаман элекке ялгышуың эчендә”, – диделәр»** («Юсуф», 94–95).

### Хәзрәти Ягъкубның күзләре ачылу

فَلَمَّا أَنْ جَاءَ الْبَشِيرُ أَلْقَيهُ عَلَى وَجْهِهِ فَارْتَدَّ بَصِيرًا قَالَ أَلَمْ أَقُلْ لَكُمْ إِنِّي أَعْلَمُ مِنَ اللَّهِ مَا لَا تَعْلَمُونَ

**«(Ләкин) сөенечле хәбәр бирүче килгәч, аны йөзенә салды, һәм ул (элекке кебек) күрә башлады. Ул (Ягъкуб): “Мин сезгә, һичшиксез, мин сез белмәгән нәрсәләрне Аллаһтан (вәхи аша) беләмен, димәгән идемме?” – диде»** («Юсуф», 96).

Күлмәкне алып килгән сөенечле хәбәрче Яһуда була. Аның: «Канлы күлмәкне кайчандыр этиемә мин алып кайткан һәм аны кайгыга салган идем. Хәзер исә бу күлмәкне янә мин илтеп бирим дә аның шатлануына сәбәп булыйм!» – дип, Мисырдан Кәнан иленә хәтле бик нык дулкынланып-дәртләнеп, яланбаш, яланаяк барганлыгы риваять кылына.

Әлеге күлмәк, Ибраһим галәйһис-сәләәм утка атылган чакта, Җәбраил галәйһис-сәләәм Җәннәттән алып чыгып биргән күлмәк була.

Хәзрәти Мәүләна Җәләлетдин Руми югарыдагы мәсьәлә белән бәйле рәвештә мондый фикерләрен белдерә:

«Йосыфның йөзендә Ягъкуб күргән гайре табигыйлекне бары ул гына күрә ала иде. Йосыфның кардәшләренә ул нурны күрү насыйп булмый. Кардәшләренең күңел дөньясы Йосыфны (чын йөзе белән) күрүдән һәм аңлаудан ерак тора».

«Үзенә хас сыйфатларны Йосыфта да күргәч, Ягъкубның күңеле аңа тартыла».

«Ягъкубта Йосыфка таба тартылу, аны тою сәләте була. Шуңа күрә Йосыф күлмәгенең исе аңа бик ерактан ук килеп җитә. Йосыфның күлмәкне күтәреп барган туганы исә бу исне сизүдән мәхрүм була».

«Чөнки Йосыфның күлмәге аның кардәшенең кулында бер әманәт булып санала. Ул кардәше күлмәкне Хәзрәти Ягъкубка алып кайтып тапшырырга җаваплы була. Ягъни кардәшенең кулында вакытта ул күлмәкне кол сатучы кулына эләккән гаҗәеп матур җариягә тиңләргә мөмкин. Бу колга асылда сатучы түгел, ә башка кеше хуҗа».

«Бик күп галим бар ки, ләкин аларның күбесе Аллаһны тану белеменнән мәхрүм. Гыйлемне үзләштерсәләр дә, Аллаһның дусты була алмаганнар».

Йосыф галәйһис-сәләәмнең күлмәге белән Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең күзләре ачылу нindidер предмет аша хәер-дога кылу, уңышка ирешүгә бер үрнәк булып карала ала.

Аяти кәримәдә әйтелә:

قَالُوا يَا أَبَانَا اسْتَغْفِرْ لَنَا ذُنُوبَنَا إِنَّا كُنَّا خَاطِئِينَ. قَالَ سَوْفَ أَسْتَغْفِرُ لَكُمْ رَبِّي إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ

**«Алар (уллары): “И, этиебез! Безнең өчен (Аллаһтан) гөнаһларыбызның ярлыкануын сора, һичшиксез, без бит гөнаһлылар булдык”, – диделәр. Ул исә (Ягъкуб): “Сезнең өчен (бераздан) Раббымнан истигъфар сораячакмын. Һичшиксез, Ул Аллаһ – Гафу итүче, Рәхимле”, – диде»** («Юсуф», 97–98).

Ягъкуб галәйһис-сәләәм: «Сезнең өчен бераздан истигъфар сораячакмын!» – дип, әүвәл мәзлум (кимсетелгән, золымга тарыган) зат тарафыннан гафу ителүләре кирәклегенә ишарәли. Шул рәвешле истигъфар кылуны Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм белән күрешкәнчегә кадәр кичектерә. Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең бу гамәлен дога-истигъфарны тагын да кулайрак, кабул ителү мөмкинлеге зуррак вакытка калдыру дип аңлатучылар да бар.

Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе, сәхәр вакытында мәчеткә килгәч, берәүнең: «Аллаһым, чакырдың – килдем; боердың – буйсындым. Инде шушы сәхәр вакытында мине ярлыка!» – дип әйткәнен ишетә. Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе бу тавышка колак сала һәм аның Габдуллаһ ибне Мәсгуд радыйаллаһу ганһенеке икәнен аңлый. Бу хәл турында Габдуллаһның үзеннән сорагач, тегесе болай ди: «Һичшиксез, Ягъкуб галәйһис-сәләәм улларына: "Сезнең өчен бераздан истигъфар сораячакмын", – дип тәүбә-истигъфарны сәхәр вакытына калдыра. Чыннан да, Аллаһ Тәгалә "Сәхәр вакытларында истигъфар кылучылар", аяте белән («Әли Гыймран», 17) әнә шундыйларны мактап искә ала» (Табәри, «Тәфсир», XIII, 85).

Бер риваятьтә Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләре тапшырыла: *«Раббыбыз һәр төн дөнья күгенә төшә*[108] *һәм: "Тәүбә итүче бармы? Аның тәүбәсен кабул итим. Дога кылучы бармы? Аның догасын кабул итим. Истигъфар кылучы бармы? Аны ярлыкыйм", – дип аваз салыр»* (Мөслим, «Мүсафирин», 168–170).

Башка бер хәдис-шәрифтә Пәйгамбәребезнең: *«Хәзрәти Ягъкуб уллары өчен истигъфар кылуны җомга төненә калдырган»*, – дигән сүзләре китерелә (Тирмизи, «Дәгъват», 114).

**Кавышу һәм чынга ашкан төш**

Хәзрәти Йосыф белән бергә Мисыр хөкемдары һәм бөтен халык, Хәзрәти Ягъкуб һәм аның гаиләсен каршыларга чыгып, сафларга тезелә. Кара-каршы килгәндә, Хәзрәти Ягъкуб, Хәзрәти Йосыф һәм андагы башка кешеләр атларыннан төшә. Аннары ике пәйгамбәр бер-берсен сагынып кочаклый.

Аллаһ Тәгалә болай ди:

فَلَمَّا دَخَلُوا عَلَى يُوسُفَ آوَى إِلَيْهِ أَبَوَيْهِ وَقَالَ ادْخُلُوا مِصْرَ إِنْ شَاءَ اللَّهُ آمِنِينَ

**«(Барысы бергә Мисырга барып), Йосыфның хозурына кергәч, ул атасы белән анасын кочаклады (үз янына урнаштырды) һәм: "Иншә Аллаһ, имин кешеләр буларак, Мисырга керегез", – диде»** («Юсуф», 99).

Бик зур әҗер-саваплар һәрдаим сабырлык кылудан, иза-җәфалардан, кыенлыклардан соң бирелә. Хәзрәти Ягъкуб галәйһис-сәләәм әлеге очрашудан соң, кулларын күтәреп, Аллаһка шөкрана белән: «Аллаһым! Йосыф өчен елауларымны, аннан аерылу аркасында сабырлыгым азаюны һәм улларымның энеләренә карата кылган эшләрен кичер!» – дип дога кыла.

108. Җәнабел-Хак вакыт һәм урын төшенчәсеннән азат. Шунлыктан хәдис-шәрифләрдәге «дөнья күгенә төшә» гыйбарәсе яшерен мәгънәле кәлимәләрдән санала һәм кешеләр аңына ярашлырак рәвештә, рухи якынаюны белдерү өчен кулланыла.

وَرَفَعَ أَبَوَيْهِ عَلَى الْعَرْشِ وَخَرُّوا لَهُ سُجَّدًا وَقَالَ يَا أَبَتِ هَذَا تَأْوِيلُ رُؤْيَايَ مِنْ قَبْلُ قَدْ جَعَلَهَا رَبِّي حَقًّا وَقَدْ أَحْسَنَ بِي إِذْ أَخْرَجَنِي مِنَ السِّجْنِ وَجَاءَ بِكُمْ مِنَ الْبَدْوِ مِنْ بَعْدِ أَنْ نَزَغَ الشَّيْطَانُ بَيْنِي وَبَيْنَ إِخْوَتِي إِنَّ رَبِّي لَطِيفٌ لِمَا يَشَاءُ إِنَّهُ هُوَ الْعَلِيمُ الْحَكِيمُ.

**«Ул атасы белән анасын тәхеткә менгерде, һәм алар (аның белән кавышканлыкларыннан) аңа сәҗдәгә капландылар. (Йосыф) әйтте: “И, әтием! Бу – минем элекке (күргән) төшемнең аңлатмасы. Раббым аны бер хакыйкать итте. Ул мине зинданнан чыгарып, шайтан минем белән кардәшләрем арасын бозганнан соң, сезне чүлдән китереп, миңа игелек кылды. Һичшиксез, минем Раббым – теләгәннәренә мәрхәмәт итүче. Һичшиксез, Ул – Белүче, Хикмәт иясе”»** («Юсуф», 100).

Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм, Аллаһның үзенә насыйп иткән нигъмәтләрнең иң югары дәрәҗәгә җиткәнен күргәч, бу дөньяның карар бирелә торган урын түгеллеген, мондагы һәрнәрсәнең фанилыгын, камиллектән соң юкка чыгу көткәнен аңлый. Үзенә бирелгән олуг нигъмәтләрне истә тоткан хәлдә, ул, Раббысына хәленнән килгән кадәр шөкер кылып, дога-мактаулар укып яшәвен дәвам итә:

رَبِّ قَدْ آتَيْتَنِي مِنَ الْمُلْكِ وَعَلَّمْتَنِي مِنْ تَأْوِيلِ الْأَحَادِيثِ فَاطِرَ السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ أَنْتَ وَلِيِّي فِي الدُّنْيَا وَالْآخِرَةِ تَوَفَّنِي مُسْلِمًا وَأَلْحِقْنِي بِالصَّالِحِينَ

**«И, Раббым! Син миңа хакимлек һәм миңа (төштә күрелгән) вакыйгаларның аңлатмасын насыйп иттең. И, күкләрнең һәм җирнең Яралтучысы! Син – дөньяда да, Ахирәттә дә минем вәлием. Мине мөселман буларак вафат иттер һәм изге кешеләр белән бергә ит»** («Юсуф», 101).

Игътибар итсәгез, әлеге аяти кәримәләрдә Йосыф галәйһис-сәләәм барлык мөэминнәргә үрнәк булырлык күркәм эш-гамәлләр күрсәтә. Аның җанын кыю максатында коега ташлаган туганнарыннан үч алырлык көч-куәт һәм хакимияткә ия була торып, аларга карата галиҗәнап мөнәсәбәт, нәзакәтлек, кече күңеллелек рухи өлгергәнлек һәм әхлакый камиллекнең иң югары дәрәҗәсенә ишарәли. Йосыф галәйһис-сәләәм коллыктан солтан дәрәҗәсенә күтәрелүен гел Аллаһның рәхмәтенә бәйләп карый һәм нәфесенә хәтта кечкенә генә дә өлеш чыгармый. Туганнары тарафыннан аңа карата кылынган иң яман гамәлләргә дә җаваптан тыела һәм, мондый хатаны шайтанга бәйләп, ул ялгышлыклары турында кардәшләренең йөзенә бәреп, исләренә төшерми. Ахырда исә Җәнабел-Хакка сыенуы да аның Аллаһ Тәгаләгә карата нинди дуслык, якынлык хисе тоюын һәм һәрдаим «соңгы сулыш» өчен борчылып йөргәнен күрсәтә. Суфиларның иң төп кануннарының берсе булган «изгеләр

белән бергә булу» сыйфатына нигезләмәнең иң ачык үрнәген Йосыф галәйһис-сәләәмнең менә шушы догасында күрәбез.

Риваятькә күрә, Хәзрәти Ягъкуб галәйһис-сәләәм, улы Йосыф галәйһис-сәләәм янында егерме дүрт ел яшәп, Мисырда вафат була. Аның васыяте кушканча, җәсәде Димәшкътә дәфен кылынган атасы Исхак галәйһис-сәләәм янына җирләнә. Хәзрәти Йосыф атасыннан соң тагын егерме өч ел яши. Аның җәсәден мисырлылар, мәрмәр сандык эченә куеп, Нил елгасына төшерәләр. Хәзрәти Йосыфны бик яратканлыктан, мисырлылар аны үз илләрендә калдырырга телиләр. Соңыннан Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм, Йосыфның гәүдәсен табып, атасы Ягъкубның янына илтеп, җир куенына иңдерә. Галәйһимәс-сәләм!..

Хәдис-шәрифтә: *«Үлем – мөэмингә бүләк ул»*, – диелә (Дәйләми, «Мүснәд», IV, 238).

Кеше үлем аша иң әүвәл үз нәфесеннән котыла, чөнки кешенең иң зур дошманы – үз нәфесе.

**«Йосыф» сүрәсенең ахыргы аятьләре**

Яһүдиләр биргән киңәшне тотып, Пәйгамбәр Әфәндебезне сынар өчен, мөшрикләр Аңа кайбер сораулар бирә. Шуннан соң Җәнабел-Хак шушы аяти кәримәләрне иңдерә.

Аллаһ Тәгалә Йосыф турында кыйссаны һәм шуңа охшаш яшерен хәбәрләрне Рәсүл Әкрәм саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез аша кешеләргә белдереп, Пәйгамбәренең һәм Китабының хак булганлыгын исбатлый. Ләкин кяферләр, барлык шушы дәлилләргә карамастан, үзләреннән һичнинди түләү көтмичә, җан-фәрман бирелеп тәблигъ эшен дәвам иткән Аллаһ Рәсүленә барыбер иман китермиләр. Аларның мондый кирелегенә бәйле рәвештә, Җәнабел-Хак Рәсүлен түбәндәге сүзләр белән юата:

ذٰلِكَ مِنْ أَنبَاءِ الْغَيْبِ نُوحِيهِ إِلَيْكَ وَمَا كُنْتَ لَدَيْهِمْ إِذْ أَجْمَعُوا أَمْرَهُمْ وَهُمْ يَمْكُرُونَ. وَمَا أَكْثَرُ النَّاسِ وَلَوْ حَرَصْتَ بِمُؤْمِنِينَ. وَمَا تَسْئَلُهُمْ عَلَيْهِ مِنْ أَجْرٍ إِنْ هُوَ إِلَّا ذِكْرٌ لِلْعَالَمِينَ

**«(Хәбибем!) Бу (Йосыф кыйссасы) Безнең сиңа вәхи белән белдергән гаиб хәбәрләрдән. Алар, хәйлә корып, үзләренең эшен кылырга карар иткәндә, син яннарында түгел идең (әлбәттә). Әмма син никадәр генә теләсәң дә, кешеләрнең күбесе иман китермәячәкләр. Син алардан моның өчен (Пәйгамбәрлек вазифаңны башкару өчен) түләү сорамыйсың. Ул (Коръән) бөтен галәмнәр өчен үгет кенә»** («Юсуф», 102–104).

Шулай ук кяферләрнең мондый инкяр итүе Рәсүлуллаһның пәйгамбәрлегенә һәм Аңа вәхи ителгән аятьләргә кагылмый:

وَكَأَيِّنْ مِنْ آيَةٍ فِي السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ يَمُرُّونَ عَلَيْهَا وَهُمْ عَنْهَا
مُعْرِضُونَ. وَمَا يُؤْمِنُ أَكْثَرُهُمْ بِاللّٰهِ إِلَّا وَهُمْ مُشْرِكُونَ

**«Күкләрдә һәм җирдә булган ничәмә могҗиза (дәлилләр) бар, алар аларның яныннан үтеп китәләр һәм йөз чөерәләр. Аларның күбесе, тиңдәш кушып, Аллаһка инанырлар»** («Юсуф», 105–106).

Ягъни алар Аллаһның барлыгын тулысынча инкяр итмәсәләр дә, Аллаһка ышанган килеш, ачыктан-ачык яки яшерен рәвештә аңа ширек кылалар.

أَفَأَمِنُوا أَنْ تَأْتِيَهُمْ غَاشِيَةٌ مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ أَوْ تَأْتِيَهُمُ السَّاعَةُ بَغْتَةً وَهُمْ لَايَشْعُرُونَ. قُلْ هٰذِهِ
سَبِيلِي أَدْعُوا إِلَى اللّٰهِ عَلَى بَصِيرَةٍ أَنَا وَمَنِ اتَّبَعَنِي وَسُبْحَانَ اللّٰهِ وَمَا أَنَا مِنَ الْمُشْرِكِينَ

**«Әллә алар Аллаһның газап пәрдәләреннән берсе аларга килүдән яки һич көтмәгәндә сәгать (кыямәт) килүеннән иминнәрме? (Хәбибем!) Әйт: “Бу минем юлым. Мин (кешеләрне) (уйламыйча, ияреп кенә түгел), аңлылык нигезендә (дәлилләргә таянып, аңнарына мөрәҗәгать итеп) Аллаһка дәгъват итәм. Мин дә, миңа ияргән кешеләр дә. Аллаһ (бөтен кимчелекле сыйфатлардан) пакь! Мин исә мөшрикләрдән булмадым”»** («Юсуф», 107–108).

Бу аяти кәримә дингә өндәүнең бары тик билгеле бер шартларда гына рөхсәт ителеп, файда китерә алганын күрсәтә. Ягъни сукырларча гамәл кылып, бер төркем батыйль максатлар белән яки нәфес теләк-омтылышларына ияреп түгел, ә киләчәкне күзаллап, үзең сөйләгәнне аңлап, ихласлык һәм эчкерсезлек белән, әдәп, нәзакәтлек һәм хикмәт кысаларыннан чыкмыйча, Аллаһ ризалыгын гына күздә тотып дәгъватта булу тиеш. Югыйсә, дин һәм диндарлык буш, мәгънәсез сүзләрдән генә гыйбарәт булып калыр.

وَمَا أَرْسَلْنَا مِنْ قَبْلِكَ إِلَّا رِجَالًا نُوحِي إِلَيْهِمْ مِنْ أَهْلِ الْقُرَى أَفَلَمْ يَسِيرُوا فِي الْأَرْضِ
فَيَنْظُرُوا كَيْفَ كَانَ عَاقِبَةُ الَّذِينَ مِنْ قَبْلِهِمْ وَلَدَارُ الْآخِرَةِ خَيْرٌ لِلَّذِينَ اتَّقَوْا أَفَلَا تَعْقِلُونَ.

**«Без синнән алда да (пәйгамбәр итеп) шәһәр халкыннан булган ирләр җибәргән идек һәм аларга вәхи иттек. Алар (кяферләр) җирдә йөреп, үзләреннән алда яшәгән кешеләрнең ахыры нинди булганын күрмәделәрме? Ахирәт йорты исә тәкъвалык ияләре өчен яхшырак. Бер дә аңламыйсызмы?»** («Юсуф», 109).

Әлеге аяти кәримә, «Аллаһ пәйгамбәр итеп фәрештәләрне җибәрсә иде!» дигән кяферләргә җавап буларак иңдерелә.

حَتَّى إِذَا اسْتَيْأَسَ الرُّسُلُ وَظَنُّوا أَنَّهُمْ قَدْ كُذِبُوا جَاءَهُمْ نَصْرُنَا
فَنُجِّيَ مَنْ نَشَاءُ وَلَا يُرَدُّ بَأْسُنَا عَنِ الْقَوْمِ الْمُجْرِمِينَ

**«Ул рәсүлләр өметләрен өзгәч һәм кешеләр аларны ялганчы итеп санийлар, дип уйлаган чакларында, аларга Безнең ярдәмебез килде, һәм Без теләгән кешеләр коткарылды. Әмма Безнең каты газабыбыз гөнаһлылар кавеменнән кире алынмас!»** («Юсуф», 110).

Коръәни-Кәримнең һәм Коръән кыйссаларының кешеләр өчен әһәмиятен белдереп, Җәнабел-Хак «Йосыф» сүрәсен болай дип тәмамлый:

لَقَدْ كَانَ فِي قَصَصِهِمْ عِبْرَةٌ لِأُولِي الْأَلْبَابِ مَا كَانَ حَدِيثًا يُفْتَرَى وَلَكِنْ تَصْدِيقَ
الَّذِي بَيْنَ يَدَيْهِ وَتَفْصِيلَ كُلِّ شَيْءٍ وَهُدًى وَرَحْمَةً لِقَوْمٍ يُؤْمِنُونَ

**«Аларның (элекке пәйгамбәрләр һәм аларның өммәтләренең) кыйссаларында акыл (һәм күңел) ияләре өчен гыйбрәт бар. Бу (Коръән) уйдырма була ала торган бер хәбәр түгел. Әмма үзеннән алдагыларны раслау, һәрбер нәрсәнең аңлатмасы (булган бу китап) иман китергән кешеләргә бер һидәят һәм бер рәхмәт!»** («Юсуф», 111).

Һичшиксез, Газыйм (бөек) булган Аллаһ һәрнәрсәне иң дөрес рәвештә бар иткән һәм булдырган!..

# РАБЫТА, ИСТИГАНӘ ҺӘМ ИСТИГАЗӘ

Тасаувыфта «салик» сүзе бер камил мөршиднең туры юлга өндәве ярдәмендә калебен тәрбияләп, күркәм әхлак үзләштерүне тәмамларга тырышкан кеше була. Бу калеб тәрбиясендә булган шәкерт мөршиднең, ягъни шәехнең биргән юнәлешен һич бозмыйча саклый, калебен пычрак нәрсәләрдән арындырырга тырыша. Буйсыну халәтен уңышлы рәвештә сакларга тырыша. Мөршид исә бу калеб тәрбиясендә юл күрсәтүче кеше була.

Рабыта бәйләнеш, мөнәсәбәт һәм очрашу дигәнне аңлата. Асылда, дөньяда рабытасыз бер генә мәхлук та юк. Рабыта матди һәм мәгънәви истиганә һәм истигазәне (ярдәм сорауны) мөмкин итә. Икенче төрле әйткәндә, рабыта мәхәббәттән гыйбарәт. Күңелдә мәхәббәтнең сафлыгын һәм яшьлеген нәкъ менә рабыта даими саклап килә.

Рабыта өч төрле була:

1. Табигый рабыта – кешенең үз якыннарына карата тойган мәхәббәте. Ананың үз баласына булган мәхәббәте кебек;

2. Гади (түбән) рабыта тыелган – шайтани һәм нәфсани омтылышларга бәйле булуны аңлата. Мәсәлән, акчага кәрт уйнаучының калебе һаман комарлы уеннар белән мәшгуль булып, гаиләсе һәм балалары турында да онытуы кебек;

3. Бөек рабыта (суфи рабыта) изге нәрсәләр һәм югары хис-тойгылар аша кешене Аллаһка юнәлдергән сәбәпләр һәм чараларга бәйләнешле булуны белдерә. Тәҗлия[109] һәм шаһитлык дәрәҗәсенә ирешкән кешеләргә карата бөек хисләр тоеп, аларның рухи байлыгыннан файдалану өчен, тәннәре һәм җаннары белән алар янәшәсендә булырга омтылу дигән сүз.

Коръәни-Кәримдә әйтелә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَكُونُوا مَعَ الصَّادِقِينَ

**«И, иман китерүчеләр! Аллаһтан куркыгыз һәм тугры кешеләр белән бергә булыгыз!»** («Тәүбә», 119).

Игътибар итегез, Җәнабел-Хак бу аяти кәримәдә: «Тугрылыклы булыгыз!» – дип әйтми, ә тәкъвалыкның саклансын өчен: «Тугрылар белән бергә

109. Тәҗлия – «шомарту» мәгънәсен белдергән бу термин тәсаувыфта күңел көзгесенең фанилык пычрагыннан, ягъни Аллаһтан башка барлык сорау-үтенечләрдән һәм фикерләрнең күплегеннән тәмам арынып, Аллаһ мәхәббәте һәм зикруллаһ нуры белән хозурлыкка ирешү, саф һәм искиткеч бер халәткә килү дигәнне аңлата.

булыгыз!» – дип әмер бирә. Моның белән кешеләрнең тугрылыклы җәмгыять эчендә илаһи коллык халәтен сакларга кирәклегенә ишарәт ителә.

Мәхәббәт һәм бергәлек шартларына туры китереп рабыта корган берәр кешенең шәхесе, рабыта корган башка берәр кешенең әхлак һәм өстенлекләренә, аның табигый сәләт-омтылышларына нисбәтле рәвештә формалашыр. Чөнки көчле кешеләрнең үз-үзен тотышы, тәртибе башкаларга тәэсир итүчән. Ягъни куәтле энергетикага ия холыкның таралу үзенчәлеге бар. Көчле холыклар – зәгыйфь холыклы бәндәләрнең илһам чыганагы. Мәрхәмәтле, фидакяр һәм тыныч кешеләрнең эш-гамәлләре алар гомер кичергән җәмгыятькә уңай тәэсир итә.

Шәхеснең үз-үзен тотышы, холкының мондый таралу үзенчәлеге уңай да, тискәре дә йогынтылы булырга мөмкин. Мәсәлән, Фиргавеннең вәзире Һаман һәм аның кебек башка кешеләре дә, идарәчеләре белән дус булу сәбәпле, вакыт узу белән Фиргавенгә охшый башлый.

Суфи рабыта рухи хис-кичерешләргә сәбәп була. Калебтән нәфсани, мин-минлек тойгылары китә, үрнәк итеп алынган камил мөршиднең сыйфатлары күчереп алына. Дөнья малы калебнең тышында гына калдырылып, бер максат буларак түгел, ә чара буларак кабул ителә.

Мөршиднең калебе нәкъ менә бер линза кебек. Сыйфатуллаһның нурлары чагылып, йөрәктәге тискәре тойгылар яна. Дөньяга караган фани ләззәтләр тәмам югала. Күркәм сыйфатлар рабыта аша мөриднең калебенә, вакыт узу белән, мәхәббәт дәрәҗәсендә тарала. Күркәм холык барлыкка килгәндә, мөрид белән мөршид бербөтенгә әверелә.

Хәдиси-шәрифләрдә болай дип тапшырыла:

*«Кеше сөйгәне белән бергә булыр»* (Бохари, «Әдәб», 96).

*«Нинди дә булса кавемгә охшарга тырышучы шулардан булыр»* (Әбү Давыт, «Либас», 4/4031).

Имам Газали куддисә сирруһ намаз укучы кешенең күңелендә хозурлык барлыкка килүнең шарт булуын әйткәннән соң: «Беренче һәм соңгы утыруда Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмне калеб күзләре белән күзаллау кирәк...» – дип, Пәйгамбәребезгә карата рабыта булдыру заруриятенә игътибар юнәлтә.[110]

### Рухи халәт чагылышлары

Югарыда әйтелгәнчә, рухи халәтләр тәэсир итү сәләтенә ия. Бу таралу үзенчәлеге төрләрен чынга ашу рәвешенә нисбәттә түбәндәгечә аерып карарга була:

110. Рабыта турында тәфсилләбрәк уку өчен карагыз: «Имандан Ихсана ТАСАВВУФ», 249–257 б.

**1. Караш (күңел күзе).**

Пәйгамбәрләр һәм әүлияларның күз карашы турында сүз бара. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез: *«Мөэминнең карашыннан сакланыгыз! Чөнки ул Аллаһның нуры белән карый»*, – дип әйткән (Тирмизи, «Тәфсир», 15).

Сәламәт калебле кешенең карашы уңай холык сыйфатлары барлыкка килүгә сәбәп булыр. Мондый шәхеснең йөрәгендәге тынычлык, фазыйләт ул караган кешенең йөрәгенә күчәр.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вәгазьләрен тыңлап, аның мөбәрәк карашларын тою бәхете тәтегәнгә, әсхабе кирамга өммәттә иң югары саналган сәхабәлек дәрәҗәсе насыйп булды. Шуңа күрә Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәрлек карашын күрмәгән мөэминнәрнең сәхабәлек дәрәҗәсенә ирешүе мөмкин түгел.

**2. Сүз.**

Нәфесен тәрбияләгән һәм калебен сафландырган кешенең сүзләрендә рухи халәтендәге кичерешләре чагылыш таба. Бу тойгылар белән әйтелгән сүзләр әңгәмәдәшенә тәэсир итә.

**3. Әңгәмә.**

Үзара гәпләшүне дә күздә тоткан мәҗлесләрдә тышкы бергәлек тә бар. Калебләрдәге төрле илаһи чагылышлар ул мәҗлестә катнашучыларга барып ирешә. Көчле холыклар зәгыйфь холыклы бәндәләрнең илһам чыганагы булып тора. Зәгыйфьләр алардан үзенә күрә бер рухи энергия ала.

**4. Калган ризык белән бәрәкәтләнү.**

Төрле вакыт һәм урыннарда сәхабәләр Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән калган мөбәрәк ризыктан бәрәкәт тапкан. Кайбер хәдисшәрифләрдә сөйләнгәнчә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез, сөт эчкән вакытта, башка сәхабәләргә дә тәкъдим иткән һәм шуның белән аны эчкән кешегә дә фазыйләте күчкән, сөт тә, бәрәкәтлегә әверелеп, һич кимемәгән.

Сәһл ибне Сәгъд радыйаллаһу ганһе риваять кыла:

«Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезгә бер эчемлек китерелде. Ул аннан бер микъдар эчте. Бу вакытта аның уң ягында бер бала, ә сул ягында өлкән яшьтәге олуг сәхабәләр утыра иде. Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм уң ягындагы балага берни белән дә чагыштырып булмастай нәзакәтле һәм түбәнчелекле рәвештә: *«Рөхсәт итсәң, бу эчемлекне башта шушы олы кешеләргә биримче?»* – дип сүз катты.

Әлеге кечкенә, ләкин акыллы бала һәркемне аптыраштa калдырырлык, әмма гыйбрәтле җавап кайтарды: «Йә, Рәсүлүллаһ! Сезнең тарафтан тәкъдим ителгән миңа насыйп ризыкны һичкемгә бирмәм!».

Шулай итеп, Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мөбәрәк кулларындагы эчемлекне шушы балага бирде» (Бохари, «Әшрибә», 19).

Әбү Әйюб әл-Әнсари радыйаллаһу ганһе Пәйгамбәр Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмне өендә кунак иткән көннәрдә, ризык әзерләп, Әфәндебезгә җибәрә. Ризыкның калган өлеше әйләнеп кайткач, Галәмнәр Әфәндесенең бармаклары кагылган урыннарны эзли торган була (Мөслим, «Әшрибә», 170–171).

Ходайбиядә сусызлык хәле килеп тугач, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез кулларын су савытына куя һәм бармаклары арасыннан чишмә кебек сулар ага башлый, су савытлары сулар белән тула һәм гаскәрләрнең суга ихтыяҗы канәгатьләндерелә (Карагыз: Бохари, «Мәнакыйб», 25).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бармакларыннан аккан бу су, һичшиксез, зәмзәмнән дә шифалы һәм изгерәк була. Чөнки ул Галәмнәр горурлыгы булган Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нурлы кулларыннан һәм мөбәрәк җисми-шәрифеннән агып чыккан.[111]

**5. Рухи халәтнең предмет аша күчерелүе.**

Бик озын чылбыр аша риваять кылынган мөтәватир бер хәдис-шәрифтә тапшырылганча, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез хөтбәләрне хөрмә төбенә менеп басып сөйли торган була. Мәчеткә мөнбәр ясагач, бу төпсәне ташлап, мөнбәргә басып сөйли башлый. Ул хөрмә бүкәне исә Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән аерылу хәсрәтеннән елый башлый. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм әлеге төпсәне сыпыргач, ул тынычланып кала (Бохари, «Мәнакыйб», 25).

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Вәйсал Карани Хәзрәтләренә җиләнен җибәрә һәм: *«Бу җиләнне кисен һәм өммәтемә дога кылсын!»* – дип әйтә (Карагыз: Мөслим, «Фәдаилүс-Сахабә», 223–225).

Йосыф галәйһис-сәләәмнең күлмәген алып Мисырдан юлга чыккан вакытта, Ягъкуб галәйһис-сәләәм аның исен хәтта Кәнан иленнән үк тоя, аны сукырайган күзләренә куеп сыпыруга, күрә башлый.

Предмет аша бәрәкәткә ирешүдән тыш, моның рухи файда ягыннан да кайбер сәбәпләре бар. Рухи фазыйләт күчешенә китерсен өчен, рабытада силсиләи шәрифә[112] уку һәм муракабә[113] дә моңа бер мисал булып тора.

111. Бу мәсьәлә турында тулырак белү өчен карагыз: «Имандан ихсана ТАСАВВУФ», 415-418 б.
112. Силсиләи-шәрифә – Пәйгамбәрләр чылбыры турында бәяннамәләр.
113. Муракабә – үзеңнең һәрвакыт Аллаһ күзәтеп торганлыгын уйлап эш йөртү.

Суфиян ибне Уйәйнә рәхмәтуллаһи галәйһи: «Изгеләр искә алынганда рәхмәт иңә!» – дигән (Аҗлуни, «Кәшфүл-Хафә», II, 70/1772).

Коръәни-Кәримдә искә алынган Әсхабе Кәһф кыйссасы да игътибарны җәлеп итә. Кыйтмир бер эт кенә булса да, изге һәм тугрылыклы кешеләрне саклаган өчен, аларның күркәм сыйфатлары Кыйтмирдә чагылыш тапкан. Шулай итеп, ул да, тугрылыклылардан булып, җәннәткә кертеләчәк.[114] Бер эт Хак Тәгаләнең изге һәм тугрылыклы колларыннан аерылмыйча, аларга тугры хезмәт итеп, бу дәрәҗәгә күтәрелгәч, хакыйкый мөэминнең дә, Аллаһ дусларына ихлас ияреп, рухи яктан зур алгарыш кичерәчәге көн кебек ачык.

Ислам дине барлыкка килгәнче, әсхабе кирам күп очракта яратылыш максатына һәм кешенең табигатенә капма-каршы булган тормыш белән яши. Ләкин һидәят юлына басканнан соң, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм хис-кичерешләренең үзләрендә чагыла башлау белән, дөньяның иң фазыйләтле кешеләренә әйләнәләр. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән чылбыр буенча тапшырылып, камил мөршидләргә ирешкән бу тойгылар «салик»ләргә рабыта һәм әңгәмәләр аша күчә. Нәтиҗәдә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең үрнәк холкы мөридкә андагы табигый сәләткә нисбәтле рәвештә күчә.

«Маидә» сүрәсенең 35 нче аяти кәримәсендә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَابْتَغُوا إِلَيْهِ الْوَسِيلَةَ

**«И иман китерүчеләр! Аллаһтан куркыгыз, Аңа якынаю юлларын (сәбәпләрен) эзләгез!..»** – диелә.

Кайбер мөфәссирләр фикеренчә, якынаю юлы, дигәндә, камил мөршиднең Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әхлагы белән тәрбияләнүе күздә тотыла.

Имам Мәлик рәхмәтуллаһи галәйһи: «Теләкләрегездә Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмне сәбәп итегез!» – дигән. Имам Шәфигый рәхмәтуллаһи галәйһи: «Теләсә нинди берәр мәсьәләдә тоткарланып калган чакта, ике рәкәгать хаҗәт намазы кылып, Әбү Хәнифә Хәзрәтләренең каберенә барам. Хаҗәтем дә шул рәвешле үтәлә...» – дигән.

Имам Җәзәри куддисә сирруһ: «Догаларыгыз кабул булсын өчен, пәйгамбәрләр һәм изге кешеләрне сәбәп итегез!» – дигән.

Аллаһ Рәсүленең исемен атап теләк теләүгә кагылышлы берничә мисал китерик.

Ибни Габбас радыйаллаһу ганһе сөйләп калдырган:

114. И.Хаккы Бурсәви. «Рухул-Бәян», V, 226 б.

«Хәйбәр яһүдиләре белән Гатафан кабиләсе арасында сугыш бара һәм Хәйбәр яһүдиләре гатафаннарга һәр бәрелештә җиңелә иде. Ахырдан: "И, Аллаһыбыз! Ахыр заманда җибәрергә вәгъдә иткән шул өмми пәйгамбәр хакы өчен, Синнән безне җиңүче кылуыңны сорыйбыз", – дип дога кылырга карар кылдылар һәм гатафаннар белән очрашкач, шул доганы кылдылар. Сугышның ахырында гатафаннар җиңелә. Ләкин яһүдиләр догаларында сәбәп иткән ахырзаман нәбие Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәр буларак җибәрелгәч, аны инкяр иттеләр. Шуңа күрә Аллаһ Тәгалә шушы аяти кәримәне вәхи итте:

وَكَانُوا مِنْ قَبْلُ يَسْتَفْتِحُونَ عَلَى الَّذِينَ كَفَرُوا فَلَمَّا جَاءَهُمْ
مَا عَرَفُوا كَفَرُوا بِهِ فَلَعْنَةُ اللهِ عَلَى الْكَافِرِينَ

**«...Аларга үзләре таныган килгәч, аны инкяр иттеләр. Үзләре элек (ул пәйгамбәрнең исемен кулланып, аның хакы өчен) кяферләргә каршы җиңү сорыйлар иде бит. Аллаһның ләгънәте (шундый) кяферләр өстенә»** («әл-Бәкара», 89) (Куртуби, II, 27; әл-Вахиди, «Әсбабүн-Нүзул», 31 б.).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең вафатыннан соң, Мәдинәдә көчле кытлык тарала. Бу хакта киңәш сорап, кешеләр Хәзрәти Гайшә радыйаллаһу ганһәгә мөрәҗәгать итә. Гайшә анабыз аларга мондый киңәш бирә: «Мөхтәрәм Пәйгамбәр Әфәндебезнең шәрәфле каберенә барып, өстеннән туфракны тәрәзә кебек ачып җибәрегез. Әфәндебез белән күк арасында бер пәрдә дә калмасын!» Шул рәвешле эшләгәч, мул итеп яңгыр ява, үләннәр яшәреп үсеп, дөяләр яхшы ук симереп китә. Хәтта бу елны «Гамул-фәтк (муллык елы)» дип атыйлар (Дарими, «Мукаддимә», 15).

Изге кешеләр исеме белән теләк теләү, ялвару турында берничә риваять тапшырылган:

Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе корылык вакытында Хәзрәти Габбас радыйаллаһу ганһене янына чакыра да, аны яңгыр яудыру өчен бер сәбәп, ярдәмче итеп карый (Бохари, «Истиска», 3).

Бер кеше ниндидер ихтыяҗ белән Госман Гаффан радыйаллаһу ганһенең янына берничә тапкыр бара, ләкин Госман радыйаллаһу ганһе аңа игътибар итми, ярдәмгә мохтаҗлыгын күрми. Бу кеше Госман ибне Хунәйф белән очраша һәм үз хәле турында аңа зарланып сөйли. Госман ибне Хунәйф аңа әйтә: «Тәһарәт алып, мәчеткә бар һәм ике рәкәгать намаз укы. Аннан соң: "Аллаһым! Рәхмәт Пәйгамбәре булган Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм хөрмәтенә Синнән сорыйм һәм Сиңа гына табынам. И, Мөхәммәд! Мин Синең белән Синең Раббыңа юнәләм, ихтыяҗымны кабул ит!" – дип дога кыл һәм теләгәнеңне сора».

Теге кеше мәчеткә барып, үзенә кушканнарның барысын да эшли һәм янәдән Госман ибне Гаффанның өенә килә. Хезмәтче, аны җитәкләп, Госман радыйаллаһу ганһе янына алып керә. Хәзрәти Госман аны янындагы ястыкка утырта. «Нинди ихтыяҗ белән килдең?» – дип сорый. Бу кеше сөйләп бирә. Хәзрәти Госман аны шундук канәгатьләндереп: «Ни өчен бүгенгә кадәр ихтыяҗыңны миңа сөйләмәдең, моннан берәр үтенечең булса, безгә кил!» – ди.

Бу кеше аның яныннан чыгып, Госман ибне Хунәйфкә юл тота һәм: «Аллаһ сиңа хәерен насыйп итсен, синең белән сөйләшкәнчегә кадәр ихтыяҗымны күрми һәм миңа игътибар да итми иде», – ди.

Шуннан соң Госман ибне Хунәйф радыйаллаһу ганһе әйтә: «Валлаһи, мин бу ысулны үзем уйлап табып сөйләмәдем. Шундый бер очракка шаһит булган идем. Бер сукыр кеше Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килеп: “Йә, Рәсүлүллаһ! Аллаһтан сорачы, минем күземнең авыруын бетерсен иде! Күземнең сукырлыгы миңа зур авырлыклар китерә”, – ди. Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: *“Теләкләреңдә сабыр ит! Бу синең өчен хәерлерәк”*, – дип әйтә. Сукыр кеше исә: “Йә, Рәсүлүллаһ! Мине кулымнан тотып йөртерлек кешем дә юк. Бу хәл миңа бик нык мәшәкать тудыра. Зинһар, күзләрем ачылсын өчен дога кыл!” – дигәч, Пәйгамбәр Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый киңәш бирә: *“Бар, тәһарәт ал! Аннан соң ике рәкәгать намаз укы! Ахырдан болай итеп дога кыл: “Аллаһым! Рәхмәт пәйгамбәре булган пәйгамбәрең Мөхәммәд белән (Аның хөрмәтенә) Синнән сорыйм һәм Сиңа сыенам. Йә, Мөхәммәд! Ихтыяҗым үтәлсен өчен, Синең белән Раббыма юнәләм! Аллаһым! Аны миңа шәфәгатьче кыл!”»* (Тирмизи, «Дәгъват», 118; Әхмәд ибне Ханбәл, «Мүснәд», IV, 138; Хәйсәми, «Мәҗмәгуз-Зәваид», II, 279).

Хәким тапшырган риваятьтә исә сукыр кешенең күзе күрә башлап, аягына басуы турында да өстәп әйтелә (Хәким, «Мүстәдрәк», I, 707–708).

Гутбә ибне Газван радыйаллаһу ганһе тапшырганча, Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез болай дигән: «*Берәрегез һичкем булмаган җирдә берәр нәрсәсен югалтса яки ярдәмгә мохтаҗ хәлдә калса:* «يَا عِبَادَ اللّٰهِ أَعِينُونِى» *“ И, Аллаһның коллары, миңа ярдәм итегез!”* – дип дәшсен. Чөнки Аллаһ Тәгаләнең сез күрми торган коллары бар» (Хәйсәми, «Мәҗмәгуз-Зәваид», X, 132; Имам Нәвәви, «әл-Әзкар», 201).

Бу хәдис-шәрифне тапшырган Имам Нәвәви Хәзрәтләре үз башыннан үткән бер вакыйганы да сөйләп калдырган: «Миңа бу хәдисне сөйләгән зат моңа охшаш бер вакыйга булуын һәм Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең әмере белән эш итүен, нәтиҗәнең төп-төгәл чынга ашуын да белдерде. Мин моңа шаккаттым. Соңрак беркөнне минем янда булган бер кешенең шул ук рәвештә дөясе ычкынып китте. Шулвакыт мин аңа бу хәдис-шәрифне сөйләп күрсәттем. Шунда ни күрик: дөя, берни булмагандай, качып китүдән ваз кичте һәм хуҗасы аны бик җиңел тотып алды».

Әбү Габдуллаһ ибни Җәлла белән булган хәлне Мансур ибне Габдуллаһ түбәндәгечә бәян кыла:

Ибни Җәлла сөйләгәннәрдән: «Мәдинәи Мөнәввәрәгә килдем. Бик мохтаҗ хәлдә идем. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең шәрәфле каберенә бардым. Сәлам бирдем һәм: “Йә, Аллаһның Рәсүле! Фәкыйрьмен һәм мохтаҗлык кичерәм! Синең яныңа мосафир булып килдем”, – дидем. Бераздан йоклап киткәнмен. Төшемдә Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез миңа бер кабартма бирде. Мин аның яртысын ашадым да уянып киттем. Кабартманың икенче яртысы исә янымда иде».[115]

Ибни Габбастан тапшырыла: «Аллаһ Рәсүлен төштә күрдем. Ул үзенең шәфкатен һәм мәхәббәтен күрсәтте. Аннан соң мөэминнәрнең аналарыннан берсен күрергә киттем. Ул миңа Аллаһ Рәсүленең көзгесен күрсәтте. Көзгегә карап, Пәйгамбәрнең нурлы йөзен күрдем, үз сурәтемне күрә алмадым...»

Әлеге хәдисләрдә белдерелгән хәлләр рабытаның чагылышы һәм нәтиҗәсе булып тора. Рабыта кылынган кешедә чынга ашу да шушы була.

Хаҗи Гобәйдуллаһ Ахрар Хәзрәтләре әйткән: «Коръәни-Кәримнең: **”И, иман китерүчеләр! Аллаһтан куркыгыз һәм тугры кешеләр белән бергә булыгыз!”** – дигән аятендәге «булыгыз!» сүзе тугры кешеләр белән даими бергә булуны белдерә.

“Кәйнунәт” (булу, бар булу) һичшиксез, мәҗбүри гамәл буларак искә алынганга, хакыйкать һәм хөкем күзлегеннән ике тарафны да үз эченә ала. Хакыйкый тараф тугрыларның мәҗлесендә алар янында күңел белән булудан гыйбарәт. Хөкем тарафы исә алар югында күз алдына китерүдән гыйбарәт».

Шушы рәвешле үк, мөршид янында аңа күрсәтелгән әдәп һәм мәхәббәтне ул югында да күрсәтү һәм аның әхлагы белән тәрбияләнүне «фәна фиш-шәйх» дип атыйлар.

Шуны аңларга кирәк: рабыта итеп сайланган шәхес, ягъни камил мөршид, Аллаһ белән кол арасындагы өченче зат түгел. Чөнки исламда монахлык юк. Мөршид бары тик мөриднең үзенә үрнәк алу өчен җибәрелгән камил шәхес кенә. Әйтик, сәяхәт иткәндә кулланган транспорт төре максат түгел, ә чара гына. Бу камил мөршидне, мөриднең калебен тәрбияләүдә юл күрсәтеп, аның эчке дөньясын Аллаһ Рәсүленең әхлагы белән зиннәтләүче Аллаһ дусты дип атый алабыз. Изгелек исә Аллаһка гына хас.

«Фәна фиш-шәйх» дәрәҗәсеннән өстенрәк «фәна фир-рәсүл» баскычы бар. Бу дәрәҗәдә тормышның һәр мизгелендә Рәсүлүллаһның хозурында кебек гамәл кылып, аның әхлагы белән тәрбияләнеп, аның белән берләшү

115. Карагыз: Кәлабазы, «Таарруф». С.Улудаг тәрҗемәсе, 214 б. Тәвәссүл мәсьәләсенә бәйле тәфсилле мәгълүмат өчен карагыз: «Имандан Ихсана ТАСАВВУФ», 399-410 б.

күздә тотыла. Бу дәрәҗәгә Әбү Бәкер Сиддыйк радыйаллаһу ганһе ирешә алган. Мондый риваять тапшырылган:

«Әбү Бәкер Сиддыйк Хәзрәтләре Аллаһ Рәсүленең рухи йогынтысы тәэсирендә, хәтта тәһарәт яңарткан чакта да Аның күз алдыннан китмәвен әйтә. Ягъни Сиддыйкый Әкбәр хәтта юыну һәм чистарыну урыннарында да Аллаһ Рәсүленең мөбарәк күренешеннән аерыла алмавы турында белдерә».

Хәзрәти Әбү Бәкер радыйаллаһу ганһедәге бу «фәна фир-рәсүл» халәтенә карата Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез вафаты алдыннан: *«Барлык ишекләр дә ябылсын, тик Әбү Бәкернеке генә калсын!»* – дип әйткән (Бохари, «Асхабүн-Нәби», 3).

Бу хәдис-шәриф үзара йогынтылы күңел халәтен никадәр күркәм белдергән. Мондый рухи халәтнең нәтиҗәсе дә:

وَهُوَ مَعَكُمْ أَيْنَ مَا كُنْتُمْ

**«… Кайда гына булсагыз да, Ул сезнең белән бергә…»** («әл-Хәдид», 4).

وَنَحْنُ أَقْرَبُ إِلَيْهِ مِنْ حَبْلِ الْوَرِيدِ

**«… Без аңа (адәм баласына) муен тамырларыннан да якынрак!»** («Каф», 16) –аятьләренең серләренә ирешүне һәм «фәна филлаһ» дәрәҗәсенең хактан да булуын раслый.

Рабытаның Коръәни-Кәримдәге башка бер дәлиле булып шушы аяти кәримә тора: **«Ул хатын аны теләде (Йосыфны үзенеке итү фикере белән яна иде). Раббысыннан борһан (дәлил һәм ярдәм) күрмәгән булса, (Йосыф та) аңа омтылыр иде. Без яманлык һәм фахишәтне аңардан шулай бордык. Һичшиксез, ул – Безнең ихлас колларыбыздан иде»** («Йосыф», 24).

Бу аятьнең тәфсирендә мөфәссирләр «Раббысыннан борһан (дәлил) күрмәгән булса» гыйбарәсендәге борһанны түбәндәгечә аңлата:

«Борһанның максаты – хатынның куркыныч нияте каршында Ягъкуб галәйһис-сәләәм сурәтенең, бармагын авызына тидергән рәвештә, Йосыфның күз алдында бер мизгелдә җанланып һәм шаккатып аңа: “Һай, үзеңне кулга ал, аннан йөз чөер!” – дип мөрәҗәгать итүеннән гыйбарәт. Шулай итеп атасының бу рәвешле күз алдында җанланып үзенә кисәтү ясаганын күргән Йосыф галәйһис-сәләәм хисләрен йөгәнли һәм чиркангыч гамәлдән тыелып кала».

Рабыта, бу аяти кәримәнең тәфсирендә ачыкланганча, Хәзрәти Йосыф Ягъкуб галәйһис-сәләәмне күз алдында күргән кебек, мөриднең дә шәехе сурәтен һәм аңа хас рухи халәтне күз алдында һәм күңелендә йөртүе була.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә сәлам-салават әйтеп, күңелдә бер мәхәббәт элемтәсе булдыру да үзенә күрә бер рабыта санала.

Кеше аңында абстракт нәрсәне ниндидер предметка яки формага бәйләмичә генә кабул итү сәләте җиңел генә барлыкка килми. Гыйлем галим кешедә, гыйшык – гашыйкта, сәнгать сәнгатькярдә күренә. Абстракт нәрсәне күренешсез кабул итү мөмкин түгел.

Оста – шәкерт, укытучы – укучы һ.б. кебек барлык мөнәсәбәтләр шулай ук рабыта белән бәйле. Рабыта аша мөршид үз калебендәге рухи халәтләрне саликкә төшендерә. Камиллеккә ирешкән мөршид белән физик янәшәлек вакытында югары хис-тойгылар кичергән кебек, ул халәтне рухи бергәлектә дә, ягъни мөршид юк чагында да дәвам иттерү рабытаның хакыйкатенә ирешү дигәнне белдерә. Чөнки Аллаһ дуслары белән һәрвакытта да янәшә, бергә булу мөмкин түгел.

Рабыта Аллаһ дусларыннан төзелгән чылбыр аша Хәзрәти Пәйгамбәрдән фазыйләт күчешен тәэмин итә. Өзлексез электр тогына тоташкан кешеләр кебек иң ахыргысы да шул ук агымны үз сәләтенә күрә кабул итә. Рабыта нәтиҗәсендә рухи ярдәм килә. Моны исә истиганә һәм истигазә дип атыйлар.

**Рабыта-и Мәүт**

Тәсаувыфта үлем белән рабыта коруны «тәфәккүри-мәүт» диләр. Үлем турында уйлануның кешедәге рухи халәткә һәм аның эш-гамәлләренә тәэсире зур. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләрендә болай диелә:

اَكْثِرُوا ذِكْرَ هَاذِمِ اللَّذَّاتِ يَعْنِى الْمَوْتَ

*«Барлык рәхәтлекләрне бөтенләе белән юк итүче үлем турында күп уйланыгыз!»* (Тирмизи, «Зүһд», 4);

كَفَى بِالْمَوْتِ وَاعِظًا

*«Үлем (сезгә) нәсыйхәтче буларак җитәр!»* (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 77).

Ибне Гомәр радыйаллаһу ганһүмә сөйләгәннәрдән:

«Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында идем. Әнсарлардан бер кеше килеп, Әфәндебезгә сәлам бирде. Аннан соң: “Йә, Аллаһның Рәсүле! Мөэминнәрнең кайсысы иң фазыйләтле?” – дип сорады. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *“Әхлагы белән иң өстен булганы!”* – диде. Ул кеше тагын: “Мөэминнәрнең иң акыллылары кемнәр?” – дип сорады. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *“Үлем турында иң күп хәтерләүче һәм үлемнән*

*соң булачакларга иң яхшы әзерләнүче. Менә болар – иң акыллы кешеләр”*, – дип җавап бирде» (Ибне Мәҗә, «Зүһд», 31/4259).

Чыннан да, «тәфәккүри-мәүт» кешенең күңел тынычлыгыннан аерган нәфес дөньясына мәхәббәтен киметә. Чөнки дөньяның вакытлы байлыкларын, мәртәбәләрен, дәрәҗәләрен һәм нәфсани матурлыкларын артык сөю һәм аларга күңел бирү гафләт кебек рухи чирләрнең беренчел сәбәбе була. Күңелебезне моның кебек бәйлелекләрдән саклар өчен, каберне искә төшерү, киләчәктә башыбыздан узачак үлем хәлләре турында уйлану безне, ихлас тәүбәгә һәм түбәнчелек белән гыйбадәт кылуга юнәлтеп, дөньяви комсызлыктан, буш теләк-омтылышлардан саклый. Дәвамлы зикерләребез һәм рабыталарыбыз, иншә Аллаһ, ахирәттә котылуга һәм бәхеткә ирешүгә сәбәп булыр.[116]

Аллаһ калебләребезне зикер һәм мәхәббәт чыганагына әверелдерсен! Амин!

Амин!..

116. Бу мәсьәләгә бәйле тәфсилле мәгълүмат алу өчен карагыз: «Имандан Ихсана ТАСАВВУФ», 255–257 б.

***Хәзрәти Ягъкуб галәйһис-сәләәм***




***Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәм***





# ХӘЗРӘТИ
# Шөгаеб
*галәйһиссәләм*

### *Күңелләрне әсәрләндергән вәгазьләре сәбәпле «Хатыйбүл Әнбия» дип йөртелгән*

# ХӘЗРӘТИ ШӨГАЕБ

### *галәйһис-сәләәм*

Ибраһим галәйһис-сәләәм яки Салих галәйһис-сәләәм нәселеннән килгән пәйгамбәр. Әнисе ягыннан Хәзрәти Лутның кызы нәселенә тоташканлыгы һәм Әйюб галәйһис-сәләәм белән ике туган балалары булганлыгы риваять кылына. Шул ук вакытта Муса галәйһис-сәләәм өчен хатынының әтисе булып тора, ягъни Муса Шөгаеб галәйһис-сәләәмнең кияве була.

Шөгаеб галәйһис-сәләәм таулы һәм урманлы ике күрше дәүләт булган Мәдйән һәм Әйкә халкына пәйгамбәр итеп җибәрелә (Хаким, «Мүстәдрәк», II, 621/4075).

Мәдйәндә туып-үскән Шөгаеб галәйһис-сәләәм ул кавемнең затлы гаиләсеннән була. Яшьлеге Мәдйән кавеме арасында уза. Бу төбәк халкы, әхлаксызлыкка бирелеп, юлдан яза. Шөгаеб галәйһис-сәләәм исә аларның әшәкелекләреннән ерак торып, саф һәм пакь тормыш алып бара. Мондый пакь тормышы һәм нәсыйхәтләре белән ул кешеләргә бер үрнәк зат була.

**Мәдйәнлеләр**

Мәдйән – Акабә култыгыннан Хумус үзәнлегенә кадәр сузылган өлкә. Мәдйән атамасы монда яшәгән бер кабилә исеме белән бәйле.

Мәдйәнлеләр бозыклыкка, Хак Тәгаләне кире кагу юлына баскан, Аллаһка гыйбадәт һәм буйсынудан баш тарткан була. Алар потларга һәм һәйкәлләргә табына. Мәдйәннең кәрван юллары уңаенда урнашканлыгы сәбәпле, аның халкы сәүдә белән шөгыльләнә. Ләкин хәйлә-мәкер киң тарала, хәтта бер төрле сәнгать һәм осталык дәрәҗәсенә җитә. Халык алыш-биреш вакытында товар үлчәгәндә, үзләре файдасына арттырып үлчи, үзләре алган әйберне аз итеп күрсәтәләр; башкаларга нидер сатканда, акчасын арттырып алып, товарны киметеп бирәләр, хәйләләп, аз нәрсәне күп итеп күрсәтергә тырышалар. Хәтта алу өчен аерым бер үлчәү, сату өчен аерым бер үлчәү куллана башлыйлар.

Бу азгын кавем кешеләрнең юлларына каршы чыгып, аларның малларыннан бер өлешне талап ала торган була. Аерым алганда, чит ил кешеләренең һәм мөһаҗирләрнең малларын төрле алдау-йолдау юллары белән үзләштерәләр. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләре тулысынча диярлек хәйләгә, алдауга, изүгә, золымга нигезләнә. Хак Тәгалә биргән мул нигъмәтләрнең кыйммәтен

белмиләр, шөкер кылмыйлар, Аллаһ кушканнарга каршы килеп һәм потларга табынып, коточкыч кяферлек упкынына чумалар. Кыскасы, мәдйәнлеләрнең дине – мәҗүсилек, сәүдәләренең нигезе – алдау, ә иң күзгә ташланып торган һөнәрләре спекуляция була. Барлык әдәп-әхлак нигезләре җимерелгән Мәдйән тулы мәгънәсендә дини, сәяси, икътисади һәм әхлакый деградация кичерә.

Мәдйәнлеләр шундый кәеф-сафалы, ваемсыз тормыш алып барганда, Аллаһ Тәгалә аларга Шөгаеб галәйһис-сәләамне җибәрә. Хәзрәти Шөгаеб аларга матур-матур вәгазь-нәсыйхәтләр сөйли, Аллаһ кушкан һәм тыйган нәрсәләр турында аңлата. Җәнабел-Хакка ширек тотмаска, бары Аңа гына гыйбадәт кылырга; алыш-бирештә, үлчәүдә гаделсез эш йөртмәскә; ахирәт көненә иман китерергә һәм җир йөзендә фетнә куптармаска кирәклеге турында хәтергә төшерә. Бөек Аллаһ газабының авырлыгы, нигъмәтенең чиксезлеген белдерә.

Аяти кәримәләрдә болай диелә:

وَإِلَى مَدْيَنَ أَخَاهُمْ شُعَيْبًا قَالَ يَا قَوْمِ اعْبُدُوا اللَّهَ مَا لَكُمْ مِنْ إِلَهٍ غَيْرُهُ وَلَا تَنْقُصُوا
الْمِكْيَالَ وَالْمِيزَانَ إِنِّي أَرَيكُمْ بِخَيْرٍ وَإِنِّي أَخَافُ عَلَيْكُمْ عَذَابَ يَوْمٍ مُحِيطٍ

**«И, кавемем! Аллаһка гыйбадәт кылыгыз, сезнең Аннан башка һичбер илаһыгыз юк. Төгәл үлчәгез һәм кешеләргә әйберләрен киметмәгез. Мин сезне иркенлектә (муллыкта) күрәм, Әмма мин сезнең өчен уратып алган бер көннең газабыннан куркамын»** («Һуд», 84).

قَالَ يَا قَوْمِ اعْبُدُوا اللَّهَ مَا لَكُمْ مِنْ إِلَهٍ غَيْرُهُ قَدْ جَاءَتْكُمْ بَيِّنَةٌ
مِنْ رَبِّكُمْ فَأَوْفُوا الْكَيْلَ وَالْمِيزَانَ وَلَا تَبْخَسُوا النَّاسَ أَشْيَاءَهُمْ وَلَا تُفْسِدُوا
فِي الْأَرْضِ بَعْدَ إِصْلَاحِهَا ذَلِكُمْ خَيْرٌ لَكُمْ إِنْ كُنْتُمْ مُؤْمِنِينَ

**«Ул әйтте: “И, кавемем! Аллаһка гыйбадәт кылыгыз, сезнең Аннан башка һичбер илаһыгыз юк. Сезгә Раббыгыздан ап-ачык бер дәлил килде: төгәл үлчәгез һәм кешеләргә әйберләрен киметмәгез. Төзәтелгәннән соң, җирдә бозыклык чыгармагыз. Әгәр иман китергән кешеләр булсагыз, бу сезнең өчен яхшырак”»** («әл-Әгъраф», 85).

يَا قَوْمِ اعْبُدُوا اللَّهَ وَارْجُوا الْيَوْمَ الْآخِرَ

**«…И, кавемем! Аллаһка гыйбадәт кылыгыз, соңгы көнне теләгез!..»** («әл-Ганкәбут», 36).

Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәм шул рәвешле Мәдйән халкына төрле хакыйкатьләрне аңлатып, тәблигъ эшен башкара. Аларны кыямәт көне һәм

илаһи хисап киләчәген расларга чакыра һәм шулчакта файда китерәчәк гамәлләр башкарырга өнди.

Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәм, аерым алганда, сәүдә эшләрендә һәм үлчәүдә алдашырга ярмаганлыгы хакында халыкны һәрдаим кисәтеп тора. Шул ук вакытта, мондый эш-гамәлләрдән баш тартып, тәүбә итмәсәләр, үзләренә бирелгән бөтен нигъмәтләрнең кире алыначагын да белдерә. Аллаһ Тәгалә бу кавемгә бик күп мал һәм нигъмәт биргән була. Тик кавем халкы, тәүбәгә килеп, шөкер итәсе урында, мәкер белән эш йөртеп, Аллаһ билгеләгән чикләрне бозуын дәвам итә.

وَيَا قَوْمِ أَوْفُوا الْمِكْيَالَ وَالْمِيزَانَ بِالْقِسْطِ وَلَا تَبْخَسُوا النَّاسَ
أَشْيَاءَهُمْ وَلَا تَعْثَوْا فِي الْأَرْضِ مُفْسِدِينَ

**«И, кавемем! Төгәл-гадел үлчәгез һәм кешеләргә әйберләрен киметмәгез (маллары мәсьәләсендә гаделсезлек кылмагыз). Һәм җирдә (көферлек кылып) бозыклык чыгармагыз!»** («Һуд», 85).

Шуннан соң Шөгаеб галәйһис-сәләәм сәүдә эшенең төп нигезләрен ачыклый. Болар – малның авырлыгын, күләмен төгәл үлчәү һәм дөрес, нормаль керемгә канәгать булу. Нормаль керем, дигәндә сәүдә һәм хезмәт иминлеге, Аллаһ каршында бәндә хакын хөрмәт итеп, йөз аклыгын саклау күздә тотыла. Шөгаеб галәйһис-сәләәм үгет-нәсыйхәтен дәвам итеп:

بَقِيَّةُ اللَّهِ خَيْرٌ لَكُمْ إِنْ كُنْتُمْ مُؤْمِنِينَ وَمَا أَنَا عَلَيْكُمْ بِحَفِيظٍ

**«Аллаһның (хәләленнән) сезгә калдырганы сезнең өчен яхшырак. Әгәр иман китергән кешеләр булсагыз. (Шул ук вакытта) мин – сезгә сакчы түгел»**, – дип әйтә («Һуд», 86). «Ягъни кылган яманлыкларыгыз аркасында мин сезгә җәза да бирә алмыйм, сез хуҗа булган нигъмәтләрнең, Аллаһны кире кагуыгыз сәбәпле, кулыгыздан тартып алынуына да каршы тора алмыйм! Мин үземә белдерелгәнне генә тапшырам!»

Югарыдагы аяти кәримәләрдә Шөгаеб галәйһис-сәләәм кавемен түбәндәге биш нәрсәгә өнди:

1. Тәүхид һәм бары тик Аллаһка гына гыйбадәт кылу;

2. Үзенең Пәйгамбәрлеген тану;

3. Үлчәүдә төгәллек, дөрес үлчәү, үлчәгәндә алдамау;

4. Кешеләрнең бер хакына да кермәү. Талау, караклык, ришвәт, юлбасарлык һ.б. барлык ачык һәм яшерен яман гамәлләрдән баш тарту;

5. Дин һәм дөнья эшләрендә бозыклык, фетнә чыгармау.

Шөгаеб галәйһис-сәләәм өндәгән бу биш нәрсәне кыскача: «Яралтучыга хөрмәт, мәхлукларга шәфкать һәм мәрхәмәт», – дип билгеләргә мөмкин. Чөнки мондый билгеләмә, тәүхид һәм Пәйгамбәрләрне тану белән бергә, барлык бәндә хакларын ихтирам итү һәм җирдә бозаклык таратмау кебек тарафларны да колачлый.

Шөгаеб галәйһис-сәләәмнең дәгъваты шактый нәтиҗәле була – ул әйләнә-тирәгә бик зур тәэсир ясый. Кешеләр төркем-төркем аның янына килеп йөри, аңа иман китерәләр һәм ул аңлатканнарны үтиләр. Аллаһка гыйбадәт кылып, сәүдәдә гаделлек белән эш итәләр. Ләкин ышанмаучылар да шактый күп була.

Иманлылар саны арту ышанмаучыларның ачуын чыгара, нормаль эшләп алган керемне азсыналар. Алар бер-берсен: «Гадәти ысул белән алынган керем белән һичкем байый алмас!» – дип, гаделсезлеккә һәм яманлыкка өндиләр.

Азгын кавем Пәйгамбәрләренә:

قَالُوا يَا شُعَيْبُ أَصَلوتُكَ تَأْمُرُكَ أَنْ نَتْرُكَ مَا يَعْبُدُ آبَاؤُنَا أَوْ
أَنْ نَفْعَلَ فِي أَمْوَالِنَا مَا نَشَاءُ إِنَّكَ لَأَنْتَ الْحَلِيمُ الرَّشِيدُ

**«Әйттеләр: “И, Шөгаеб! Аталарыбыз табынган нәрсәләрне һәм малларыбызны теләгәнебезчә тотуны калдырырга сиңа намазың әмер итәме әллә? Һичшиксез, син бит – тыйнак һәм төпле кешесең!”»** («Һуд», 87).

Монда «намаз» дигән сүздә дин күздә тотыла, чөнки иң колачлы һәм иң зур гыйбадәт буларак, намаз бөтен динне белдерә, дияргә мөмкин. Бу күзлектән караганда, намаз иң мөһим гыйбадәт төре булып тора.

قَالَ يَا قَوْمِ أَرَأَيْتُمْ إِنْ كُنْتُ عَلَى بَيِّنَةٍ مِنْ رَبِّي وَرَزَقَنِي مِنْهُ رِزْقًا حَسَنًا وَمَا أُرِيدُ أَنْ أُخَالِفَكُمْ
إِلَى مَا أَنْهِيكُمْ عَنْهُ إِنْ أُرِيدُ إِلَّا الْإِصْلَاحَ مَا اسْتَطَعْتُ وَمَا تَوْفِيقِي إِلَّا بِاللَّهِ عَلَيْهِ تَوَكَّلْتُ وَإِلَيْهِ أُنِيبُ

**«(Шөгаеб) әйтте: “И, кавемем! Әгәр мин Раббымнан (бирелгән) ап-ачык бер дәлилгә таянган булсам һәм Ул миңа Үзеннән сезгә күренмәгән хәерле бер ризык биргән булса (моңа ни диярсез)? Мин үзем сезне тыйган нәрсәдә сезгә каршы төшәргә теләмим. Мин көчемнән килгән кадәр төзеклек телим. Миңа (уңышка ирешүдә) Аллаһ кына ярдәм итә. Мин Аңа гына тәвәккәл иттем һәм Аңа гына юнәлдем”»** («Һуд», 88).

Шөгаеб галәйһис-сәләәм бу аяти кәримәдәге «Сезне тыйган нәрсәдә сезгә каршы төшәргә теләмим» гыйбарәсе белән: «Сезгә бары үзем эшләгән нәрсәләрне генә кушам. Әгәр сезгә берәр нәрсәне тыям икән, ул нәрсәдән беренче булып баш тарткан кеше мин булачакмын», – дигәнне белдерә.

Дингә өндәгәндә мондый нәзакәтлелек осталыгы Җәнабел-Хак мактаган мөһим үзенчәлек булып тора. Киресенчә эш йөртү исә катгый рәвештә тыела һәм гаепләнә. Әйтик, соңгы вакытларда Исраил угыллары голәмәләренең холыклары бозыла. Шул сәбәпле Аллаһ Тәгалә аларга:

أَتَأْمُرُونَ النَّاسَ بِالْبِرِّ وَتَنْسَوْنَ أَنْفُسَكُمْ وَأَنْتُمْ تَتْلُونَ الْكِتَابَ أَفَلَا تَعْقِلُونَ

**«Әллә сез кешеләргә игелек әмер итеlә торып та, үз-үзләрегезне онытасызмы? Сез бит китап (Тәүратны) укыйсыз! Һаман (кылган гамәлләрегезнең яманлыгын аңлап) акылга утырмыйсызмы?»** – дип мөрәҗәгать итә («әл-Бәкара», 44).

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезнең бу мәсьәләдә болай дигәне тапшырыла:

*«Кыямәт көнне бер кешене алып килерләр һәм җәһәннәмгә ташларлар. (Ут эсселеге аркасында) корсак тирәсендәге бөтен эчке органнар (эчәклекләр, бөерләр һ.б.) тышка атылып чыгар. Бу кеше ишәк тегермән ташын тартып әйләнеп йөргән кебек, әйләнә башлар. Җәһәннәм әһеле җыелып: "Әй, фәлән, сиңа ни булды? Син безне игелекле гамәлләргә өндәп, яманлыклардан тыя идең түгелме?" – дип сорыйлар. Теге кеше: "Әйе, мин сезне игелекле гамәлләргә өндәдем, ләкин үзем алай эшләми идем. Сезне яманлыклардан тыйдым, тик аларны үзем кыла идем", – дип җавап бирер»* (Мөслим, «Зүһд», 51/2989).

Шөгаеб галәйһис-сәләәм, ару-талу белмичә, тәблигъ эшен дәвам итә. Фәкать азгын кавем Шөгаеб галәйһис-сәләәмнең бу киңәш-нәсыйхәтләрен тыңламый, азгынлыкларын көннән-көн арттыра баралар. Көчле бер нәсел вәкиле булганга күрә, Хәзрәти Шөгаебкә ниндидер начарлык кыла алмасалар да, аңа иман китерүчеләргә янаудан, зыян салудан тыелмыйлар. Хәзрәти Шөгаеб бу мәсьәләдә аларны кисәтеп куя:

وَلَا تَقْعُدُوا بِكُلِّ صِرَاطٍ تُوعِدُونَ وَتَصُدُّونَ عَنْ سَبِيلِ اللَّهِ مَنْ آمَنَ بِهِ وَتَبْغُونَهَا
عِوَجًا وَاذْكُرُوا إِذْ كُنْتُمْ قَلِيلًا فَكَثَّرَكُمْ وَانْظُرُوا كَيْفَ كَانَ عَاقِبَةُ الْمُفْسِدِينَ

**«Сез Аңа ышанган кешеләрне куркытып һәм Аллаһның юлыннан яздырып, аны бозмакчы булып һәр юлда утырмагыз. Хәтерләгез, сез бик аз идегез, Ул исә сезне күбәйтте. Карагыз, бозыклык кылучыларның ахыры нинди булды!»** («әл-Әгъраф», 86).

Бөтен авырлыкларга карамастан, Шөгаеб галәйһис-сәләәм кавемен һидәяткә чакырудан туктамый. Ул Ибраһим галәйһис-сәләәмгә иңдерелгән Бераллалык – хәниф дине хөкемнәре кушканча гамәл кыла. Шөгаеб галәйһис-сәләәмнең пәйгамбәрлеге Димәшккъкә кадәр колач җәя. Аллаһка мәхәббәт белән янган мөэмин җаннар, аны күрер өчен, Мәдйәнгә киләләр. Мәдйән

халкы исә, Шөгаеб галәйһис-сәләәмне күреп, илаһи хөрмәт казанырга теләгән мөэминнәрнең юлларына каршы төшеп, төрлечә комачауларга тырыша. Мондый эш шайтанга буйсынуның ачык чагылышы булып тора, чөнки шайтан Җәнабел-Хак катыннан куылганда, үз ниятләрен ачып сала:

قَالَ فَبِمَا أَغْوَيْتَنِي لَأَقْعُدَنَّ لَهُمْ صِرَاطَكَ الْمُسْتَقِيمَ. ثُمَّ لَآتِيَنَّهُمْ مِنْ بَيْنِ أَيْدِيهِمْ وَمِنْ خَلْفِهِمْ وَعَنْ أَيْمَانِهِمْ وَعَنْ شَمَآئِلِهِمْ وَلَا تَجِدُ أَكْثَرَهُمْ شَاكِرِينَ

**«Ул әйтте: “Мине аздырганың өчен, мин Синең туры юлыңда, һичшиксез, аларга (колларыңа) каршы утырачакмын. Аннары мин аларга – алларыннан һәм артларыннан, уңнарыннан һәм сулларыннан киләчәкмен, һәм Син аларның күпчелеген шөкер итүчеләр буларак тапмаячаксың”»** («әл-Әгъраф», 16–17).

Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәм кавемен:

1. Юлбасарлык ысулы белән кешеләргә һөҗүм итеп, янап-куркытып, аларны җәфалаудан;

2. Кешеләрнең Аллаһка иман китерүләренә комачаулаудан;

3. Мөэминнәрне һәм иманга килергә җыенган затларны, төрле шикшөбһәләр һәм икеләнүләргә батырып, дин юлында читкә тайпылдырудан тыярга тырыша.

**Соңгы кисәтүләр**

Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәм кавеменең әшәке гамәлләренә, Аллаһка буйсынмауларына кайгыра, аларны җаһиллек йокысыннан бик зур сабырлык белән уятырга омтыла. Иң ахырда аларны болай дип кисәтә:

وَيَا قَوْمِ لَا يَجْرِمَنَّكُمْ شِقَاقِي أَنْ يُصِيبَكُمْ مِثْلُ مَا أَصَابَ قَوْمَ نُوحٍ أَوْ قَوْمَ هُودٍ أَوْ قَوْمَ صَالِحٍ وَمَا قَوْمُ لُوطٍ مِنْكُمْ بِبَعِيدٍ

**«И, кавемем! Миңа каршы төшүегез Нухның кавеменә, яки Һудның кавеменә, яки Салихның кавеменә килгән нәрсәләрнең бер охшашын сезгә дә китермәсен. Лутның кавеме дә сездән һич ерак түгел»** («Һуд», 89).

Ягъни телгә алынган бу кавемнәр дә сезнең чорга якын бер заманда һәлак ителгән. Димәк, һәлак булган кавемнәрнең вакыт ягыннан сезгә иң якыннары нәкъ менә шулар. Көферлектә, әшәкелекләрдә һәм һәлакәткә китергән сәбәпләрдә сездән әллә ни ерак түгелләр иде. Шунлыктан һәлак ителделәр дә. Сез алардан гыйбрәт алырга тиеш!..

وَاسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ ثُمَّ تُوبُوا إِلَيْهِ إِنَّ رَبِّي رَحِيمٌ وَدُودٌ

**«Сез Раббыгыздан ярлыкау сорагыз, шуннан соң Аңа тәүбә кылыгыз. Һичшиксез, минем Раббым – Рәхимле, (мөэминнәрне) Яратучы»** («Һуд», 90).

Кавемнең мөшрик җитәкчеләре Хәзрәти Шөгаебнең бу тәкъдимнәре белән килешми:

قَالُوا يَا شُعَيْبُ مَا نَفْقَهُ كَثِيرًا مِمَّا تَقُولُ وَإِنَّا لَنَرِيكَ فِينَا ضَعِيفًا وَلَوْلَا رَهْطُكَ
لَرَجَمْنَاكَ وَمَا أَنْتَ عَلَيْنَا بِعَزِيزٍ. قَالَ يَا قَوْمِ أَرَهْطِي أَعَزُّ عَلَيْكُمْ مِنَ اللَّهِ
وَاتَّخَذْتُمُوهُ وَرَاءَكُمْ ظِهْرِيًّا إِنَّ رَبِّي بِمَا تَعْمَلُونَ مُحِيطٌ

**«Әйттеләр: “И, Шөгаеб! Сөйләгән нәрсәләреңне аңламыйбыз. Без сине арабызда бер зәгыйфь дип күрәбез. Синең кабиләң булмаса, сине ташлар атып үтергән булыр идек. Синең безгә һич кадерең юк (син бездән өстен түгел)”». (Шөгаеб) әйтте: «И, кавемем! Минем кабиләм сезнең өчен Аллаһтан да кадерлерәкмени, Аңа (Аллаһның әмерләренә) артыгыз белән борылдыгызмыни? Һичшиксез, минем Раббым сезнең ни кылганнарыгызны чолгап алган»** («Һуд», 91–92).

Бу азгын кавемнең иман китерүенә өметен өзгәч, Шөгаеб галәйһис-сәләәм аларның язмышын Аллаһка тапшыра. Инде башка бер чарасы да калмый. Шулай да, бәлки, гыйбрәт алырлар, дип, аларга илаһи газап турында искә төшерә:

وَإِنْ كَانَ طَآئِفَةٌ مِنْكُمْ آمَنُوا بِالَّذِي أُرْسِلْتُ بِهِ وَطَآئِفَةٌ لَمْ يُؤْمِنُوا
فَاصْبِرُوا حَتَّى يَحْكُمَ اللَّهُ بَيْنَنَا وَهُوَ خَيْرُ الْحَاكِمِينَ

**«Әгәр сездән бер өлешегез (минем белән) җибәрелгән нәрсәгә ышанса, икенчеләрегез ышанмаса, Аллаһ арабызда хөкем биргәнчегә кадәр сабыр итегез. Ул бит – хакимнәрнең иң яхшысы»** («әл-Әгъраф», 87).

Ләкин мәдйәнлеләр янә Шөгаеб галәйһис-сәләәмне ялганда гаепли. Үзен һәм аңа иман китерергә телгәннәрне дә Мәдйәннән куып чыгару белән яныйлар. Хәзер инде алар иманлы бәндәләрнең үз араларында яшәвендә дә куркыныч күрә башлый:

قَالَ الْمَلَأُ الَّذِينَ اسْتَكْبَرُوا مِنْ قَوْمِهِ لَنُخْرِجَنَّكَ يَا شُعَيْبُ وَالَّذِينَ آمَنُوا
مَعَكَ مِنْ قَرْيَتِنَا أَوْ لَتَعُودُنَّ فِي مِلَّتِنَا قَالَ أَوَلَوْ كُنَّا كَارِهِينَ

**«Кавеме эченнән тәкәбберләнгән олуг кешеләр: “И, Шөгаеб! Без сине дә, сиңа иман китергән кешеләрне дә, һичшиксез, синең белән бергә өлкәбездән куачакбыз, яки син безнең динебезгә кайтачаксың”», – диде. Ул (Шөгаеб) исә әйтте: «Без теләмәгән кешеләр булсак тамы?»** («әл-Әгъраф», 88).

Һәм өстәп болай ди:

قَدِ افْتَرَيْنَا عَلَى اللّٰهِ كَذِبًا إِنْ عُدْنَا فِي مِلَّتِكُمْ بَعْدَ إِذْ نَجَّينَا اللّٰهُ مِنْهَا وَمَا يَكُونُ لَنَا أَنْ نَعُودَ فِيهَا إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ رَبُّنَا وَسِعَ رَبُّنَا كُلَّ شَيْءٍ عِلْمًا عَلَى اللّٰهِ تَوَكَّلْنَا رَبَّنَا افْتَحْ بَيْنَنَا وَبَيْنَ قَوْمِنَا بِالْحَقِّ وَأَنْتَ خَيْرُ الْفَاتِحِينَ

**«Аллаһ безне аннан коткарганнан соң, сезнең динегезгә кайтсак, Аллаһка карата ялган уйдырмада булырбыз. Раббыбыз булган Аллаһ теләмәсә, безгә аңа кайтырга ярамас. Раббыбыз һәрнәрсәне гыйлеме белән уратып алган. Без Аллаһка гына тәвәккәл кылдык. И, Раббыбыз! Безнең белән кавемебез арасында хак белән хөкем бир. Син бит – хөкем бирүчеләрнең иң яхшысы»** («әл-Әгъраф», 89).

Бу аятьтә Шөгаеб галәйһис-сәләәм кавеменең элекке дингә кире кайту турында тәкъдимен кире кага, ләкин бу эштә Аллаһ тарафыннан теләк белдерелүен чыгарма итеп куя. Аның шул рәвешле гамәл кылуы – үзен Аллаһ ихтыярына тапшыруын белдергән бер билге. Чөнки пәйгамбәрләр һәм әүлиялар һәрвакыт Аллаһның газабыннан һәм үз хәлләренең начарга таба үзгәрүеннән курыкканнар.

Шунлыктан Шөгаеб галәйһис-сәләәм: «Аллаһның динен ташлап, сезнең динегезгә кайтуыбыз килешле нәрсә түгел. Ләкин Аллаһ безнең һәлак ителүебезне теләсә, һичнәрсә әйтә алмаячакбыз, чөнки бөтен эшләребез Аның кулында. Ул теләгән кешене итагате сәбәпле бәхетле итәр; теләгәнен исә гөнаһлары аркасында җәзалар», – дип аңлата.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез дә һәрдаим мондый доганы укып йөргән:

اَللّٰهُمَّ مُصَرِّفَ الْقُلُوبِ! صَرِّفْ قُلُوبَنَا عَلَى طَاعَتِكَ

*«И, күңелләрне хөкем итүче Аллаһым! Йөрәкләребезне Сиңа гыйбадәткә әзер ит!»* (Мөслим, «Кадәр», 17).

Шөгаеб галәйһис-сәләәмнең бөтен үгет-нәсыйхәтләренә карамастан, киребеткән кавем һичтөрле акылга килми, үзләре иман китермәү генә түгел, иманга килгән мөэминнәргә дә түзеп тора алмыйлар. Аларны ачуланалар, һәрвакыт янап-куркытып яшиләр. Аллаһ динен кабул итү өчен килгәннәрнең

юлларына аркылы төшеп, Хәзрәти Шөгаебне яманлыйлар, аның янына килүчеләрне иман китерүдән баш тарттырырга маташалар. Аларның бу гамәле аяти кәримәдә түбәндәгечә искә алына:

وَقَالَ الْمَلَأُ الَّذِينَ كَفَرُوا مِنْ قَوْمِهِ لَئِنِ اتَّبَعْتُمْ شُعَيْبًا إِنَّكُمْ إِذًا لَخَاسِرُونَ

**«Кавеме эченнән кяфер булган олуг кешеләре әйтте: “Шөгаебкә иярсәгез, һичшиксез, үз-үзләренә зарар китерүчеләрдән булырсыз!”»** («әл-Әгъраф», 90).

**Өстән килгән куркыныч тавыш**

Шөгаеб галәйһис-сәләәмнең юлдан язган бу кешеләргә тәэсир итәрлек һичбер чарасы калмый. Ул болай дип кисәтү ясый:

وَيَا قَوْمِ اعْمَلُوا عَلَى مَكَانَتِكُمْ إِنِّي عَامِلٌ سَوْفَ تَعْلَمُونَ مَنْ يَأْتِيهِ
عَذَابٌ يُخْزِيهِ وَمَنْ هُوَ كَاذِبٌ وَارْتَقِبُوا إِنِّي مَعَكُمْ رَقِيبٌ

**«И, кавемем! Сез булган көчегезгә тырышыгыз. Һичшиксез, мин дә (вазифамда) тырышачакмын. Кемгә хурлыклы газап киләчәген һәм кемнең ялганчы булачагын тиздән беләчәксез. Көтегез, мин дә сезнең белән көтәчәкмен»** («Һуд», 93).

وَلَمَّا جَاءَ أَمْرُنَا نَجَّيْنَا شُعَيْبًا وَالَّذِينَ آمَنُوا مَعَهُ بِرَحْمَةٍ مِنَّا
وَأَخَذَتِ الَّذِينَ ظَلَمُوا الصَّيْحَةُ فَأَصْبَحُوا فِي دِيَارِهِمْ جَاثِمِينَ

**«Әмеребез килгәч, Шөгаебне һәм аның янындагы иман китергән кешеләрне рәхмәтебез белән коткардык. Золым иткән кешеләрне исә тавыш тотты, һәм алар йортларында йөзтүбән капланган булдылар»** («Һуд», 94).

Әлеге вазгыять башка сүрәдә болай сурәтләнә:

فَأَخَذَتْهُمُ الرَّجْفَةُ فَأَصْبَحُوا فِي دَارِهِمْ جَاثِمِينَ. الَّذِينَ كَذَّبُوا شُعَيْبًا
كَأَنْ لَمْ يَغْنَوْا فِيهَا الَّذِينَ كَذَّبُوا شُعَيْبًا كَانُوا هُمُ الْخَاسِرِينَ

**«Аларны җир тетрәү тотты һәм алар өйләрендә җиргә капланып калганнарга әверелделәр. Шөгаебне ялганчыга санаучылар гүя анда һич яшәмәгән кебек булдылар. Шөгаебне ялганчыга санаучылар хәсрәттә булдылар»** («әл-Әгъраф», 91–92).

Шул рәвешле Мәдйән халкы бозыклык, мәкерлек, гаделсезлек, Аллаһка һәм аның пәйгамбәренә каршы килү һ.б. яман, әшәке гамәлләренең җәзасын татый. Бу җәза залимнәрнең котылгысыз ахыры булып тора һәм андый залимнәр кызгануга лаек түгел:

فَتَوَلَّى عَنْهُمْ وَقَالَ يَا قَوْمِ لَقَدْ أَبْلَغْتُكُمْ رِسَالَاتِ رَبِّي
وَنَصَحْتُ لَكُمْ فَكَيْفَ آسَى عَلَى قَوْمٍ كَافِرِينَ

**«(Шөгаеб) алардан йөз чөерде дә (күңеленнән): “И, кавемем! Мин сезгә Раббымның рисаләтен ирештердем һәм сезгә игелек кенә теләдем. Кяферләр кавеме өчен мин ничек көеним?” – диде»** («әл-Әгъраф», 93).

كَأَنْ لَمْ يَغْنَوْا فِيهَا أَلَا بُعْدًا لِمَدْيَنَ كَمَا بَعِدَتْ ثَمُودُ

**«Гүяки алар анда һич яшәмәгәннәр дә. Сәмуд ерак булган кебек, (Аллаһның рәхмәтеннән) Мәдйән дә ерак булсын»** («Һуд», 95).

Шөгаеб галәйһис-сәләамнең кавеме дә, Сәмуд кавеме кебек үк, үгет-нәсыйхәткә колак салмаганнары өчен, куркыныч тавыш һәм гөрелте белән һәлак ителә. Боларның бертөрле җәзалануы яман әхлаклары ягыннан бер-берсенә охшаганлыгына ишарәли. Аллаһның рәхмәтеннән мәхрүм калганга күрә, ике кавемгә дә бер үк төрле бәддога укыла һәм Мәдйән кавеме бу мәсьәләдә Сәмуд кавеменә охшатыла.

Сәмуд кавемен җир астыннан, Мәдйән халкын исә өстән килгән тавыш һәлак итә. Шул рәвешле алар, Аллаһның рәхмәтеннән ерагаеп, ике дөньяның да хәсрәтенә һәм газабына дучар ителә.

**Әйкәлеләр**

«Әйкә» – «куе урман» дигән сүз. Географик яктан Кызыл диңгез ярыннан Мәдйәнгә кадәр сузылган өлкәнең атамасын белдерә. Монда яшәүчеләрне әйкәлеләр дип атыйлар.

Мәдйәнлеләр кебек үк һәртөрле байлык, муллык һәм нигъмәтләр эчендә яшәгән, ләкин тәүхид һәм һидәяттән читкә тайпылган әйкәлеләргә туры юлны күрсәтү Шөгаеб галәйһис-сәләамгә йөкләнә. Нәкъ Мәдйән халкы кебек, әйкәлеләр дә Шөгаеб галәйһис-сәләамне алдашуда гаепле.

Аллаһ Тәгалә аяти кәримәләрдә болай ди:

كَذَّبَ أَصْحَابُ الْأَيْكَةِ الْمُرْسَلِينَ

**«Әйкә халкы да бөтен җибәрелгәннәрне (пәйгамбәрләрне) ялганчы дип санады»** («әш-Шугара», 176).

وَإِنْ كَانَ أَصْحَابُ الْأَيْكَةِ لَظَالِمِينَ

**«Һичшиксез, куе агачлыкта яшәүчеләр дә (Әйкә халкы да) залим кешеләр иде»** («әл-Хижр», 78).

إِذْ قَالَ لَهُمْ شُعَيْبٌ أَلَا تَتَّقُونَ. إِنِّي لَكُمْ رَسُولٌ أَمِينٌ. فَاتَّقُوا اللهَ وَأَطِيعُونِ.
وَمَا أَسْأَلُكُمْ عَلَيْهِ مِنْ أَجْرٍ إِنْ أَجْرِيَ إِلَّا عَلَى رَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Шөгаеб аларга әйтте: "(Аллаһка каршы килүдән) һич курыкмыйсызмы? Һичшиксез, мин сезгә ышанычлы бер илчемен. Аллаһтан куркыгыз һәм миңа итагать итегез. Мин бит сездән моның өчен түләү сорамыйм. Минем әҗерем – Аллаһта гына"»** («әш-Шугара», 177–180).

Аллаһның пәйгамбәрләре кешеләр каршына ике сыйфатта чыгалар:

1. Алардан һичберсе түләү таләп итми һәм үз мәнфәгатен кайгыртмый, әҗер-савапның бары Аллаһтан гына икәнен белдерәләр;

2. Һәркем өчен үсвәи-хәсәнә, ягъни фазыйләт үрнәге булып торалар. Аларга сүз һәм гамәлдә бер булу хас, тормышлар үзләре өйрәткән хөкемнәргә туры килә.

Әлеге ике сыйфатның әһәмиятенә «Йәсин» сүрәсендә дә игътибар юнәлтелә. Хәбиб Нәҗҗар, Әсхабе Карьяне иманга чакырырга килгәч, кавеменә:

«Әй, карья ияләре! Сезгә килгән бу затлар сездән берәр түләү сорыйлармы? Бу бәндәләр камил холыклы (үсвәи-хәсәнә) түгелме? Чынлыкта бу затлар сездән акча сорамыйлар, һидәяткә туры юл (ягъни фазыйләтле тормыш) белән баручылар, шулай икән, сез дә аларга итагать кылыгыз!» – дип, аларны саусәламәт акыллы булырга өнди.[117]

Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәм әйкәлеләргә вәгазь-нәсыйхәтен болай дип дәвам итә:

أَوْفُوا الْكَيْلَ وَلَا تَكُونُوا مِنَ الْمُخْسِرِينَ. وَزِنُوا بِالْقِسْطَاسِ الْمُسْتَقِيمِ. وَلَا تَبْخَسُوا النَّاسَ أَشْيَاءَهُمْ وَلَا تَعْثَوْا فِي الْأَرْضِ مُفْسِدِينَ. وَاتَّقُوا الَّذِي خَلَقَكُمْ وَالْجِبِلَّةَ الْأَوَّلِينَ

**«Үлчәүне тулы итегез һәм (кешеләрнең хакын) киметүчеләрдән булмагыз. Төгәл мизан белән үлчәгез. Әйберләрен кешеләргә киметмәгез. Явызлык кылган кешеләр буларак, җирдә бозыклык чыгармагыз! Сезне дә, әүвәлге буыннарны да яралткан Заттан (Аллаһтан) куркыгыз!»** («әш-Шугара», 181–184).

117. Карагыз: «Йәсин» сүрәсе, 21.

قَالُوا إِنَّمَا أَنْتَ مِنَ الْمُسَحَّرِينَ. وَمَا أَنْتَ إِلَّا بَشَرٌ مِثْلُنَا وَإِنْ نَظُنُّكَ لَمِنَ الْكَاذِبِينَ. فَأَسْقِطْ عَلَيْنَا كِسَفًا مِنَ السَّمَاءِ إِنْ كُنْتَ مِنَ الصَّادِقِينَ

**«Алар әйттеләр: ”Син бит сихерләнгәннәрдән. Син бит безнең кебек бер кешесең! Без сине ялганчы дип саныйбыз. Өстебезгә күктән берәр кисәк төшер, әгәр дөресен сөйләсәң!”»** («әш-Шугара», 185–187).

**Күктән төшкән газап – көйдерүче ялкын**

Аллаһка каршы килергә җөрьәт итеп, үзләренә газап сораган кавеменә мөрәҗәгать итеп:

قَالَ رَبِّي أَعْلَمُ بِمَا تَعْمَلُونَ

**«Шөгаеб (аларга) әйтте: ”Минем Раббым сезнең ни кылганнарыгызны яхшырак белә”»** («әш-Шугара», 188).

Шөгаеб галәйһис-сәләәм Аллаһка дога кыла. Алар үзләренә сораган газап килсен өчен, Хак Тәгаләгә ялвара. Шундук эссе җилләр исә башлый. Зәңгәр төстәге чебеннәр килеп чыгып, алар өстенә ябырыла. Кяферләр чарасыз кала. Көннең эсселеге дә тора-тора арта. Кешеләр агымсулы җирләргә, агачлыкларга, күләгәле урыннарга качыша. Ләкин эсселек, корылык көннән-көн көчәя бара. Шулвакыт Җәбраил галәйһис-сәләәм, бер болыт алып килеп, аны шәһәрнең читендә туктата. Кяферләр бу болытны күргәч, җиләс күләгәсе бар, дип уйлап, барысы бергә шул болыт астына йөгерешәләр. Бөтенесе дә шунда җыелгач: «Әй, әйкәлеләр! Пәйгамбәрегезне ялганчы дип санап, һич килмәячәк, дип уйлаган ачы газапны татыгыз! Сез каршыларына басып сәҗдә кыла торган потларга да әйтегез, көчләре җитсә, сезне коткарсыннар!» – дигән бер тавыш яңгырый.

Кяферләр йөгерә-чаба җыелган болыттан алар өстенә ут һәм очкыннар ява башлый. Кяферләрнең һәрнәрсәсе – агачлары, хәтта ташлары да яна...

Аяти кәримәдә болай дип хәбәр ителә:

فَكَذَّبُوهُ فَأَخَذَهُمْ عَذَابُ يَوْمِ الظُّلَّةِ إِنَّهُ كَانَ عَذَابَ يَوْمٍ عَظِيمٍ. إِنَّ فِي ذَلِكَ لَآيَةً وَمَا كَانَ أَكْثَرُهُمْ مُؤْمِنِينَ. وَإِنَّ رَبَّكَ لَهُوَ الْعَزِيزُ الرَّحِيمُ

**«Алар аны (Шөгаебне) ялганчы дип санадылар, һәм аларны болыт (күләгә) көненең газабы тотты. Һичшиксез, ул олуг көннең газабы иде. Һичшиксез, монда бер билге бар. Әмма аларның күбесе ышанган кемсәләр булмады. Һичшиксез, синең Раббың – Бөек, Рәхимле (киң мәрхәмәт иясе)»** («әш-Шугара», 189–191).

Шөгаеб галәйһис-сәләм пәйгамбәр итеп җибәрелгән кавемнәрдән Мәдйән халкы – Җәбраил галәйһис-сәләмнең куркыныч тавышы һәм зилзилә белән, әйкәлеләр исә күләгә дип алданган болыттан яуган утлар белән һәлакәткә дучар ителә.

**Һәлак ителгәннән соң**

Башбирмәс кавемнәрнең һәлакәтеннән соң, Шөгаеб галәйһис-сәләм Мәдйәндә яшәп кала. Шулвакытта өйләнеп, ике кызы туа.

Шөгаеб галәйһис-сәләм пәйгамбәрләр арасында «Хатибүл-Әнбия» дип йөртелә, чөнки ул кавеме белән бик матур сөйләшә һәм аларның сорауларына тулы һәм ышандырырлык итеп җаваплар бирә торган була. Ул бик күп намаз укый, бәндә хакын хөрмәт итүгә һәрчак игътибар бирә. Аеруча үлчәү җиһазларында бәндә хакы бозылмасын өчен, кулыннан килгәннең барсын да эшли, башкаларның хак һәм хокукларын сакларга кирәклеге фикерен таратуга вакыт кызганмый.

Шөгаеб галәйһис-сәләмнең тагын үзенчәлеге – бик күп күз яше түккән пәйгамбәр булуы. Яше өлкәнәйгәч, күзләре шактый начарлана, тәне дә хәлсезләнә. Берничә тапкыр ул күзләре тәмам сукыраерлык итеп елый. Җәнабел-Хак аңа янә күз күремен кайтарып: «И, Шөгаеб! Нинди елау инде бу? Җәннәткә эләгү теләгеме, әллә җәһәннәмнән куркумы?» – дип вәхи аша сорау биргәч, Шөгаеб галәйһис-сәләм: «Йә Раббы! Син бу елавымның җәннәткә эләгергә теләвемнән дә, җәһәннәмнән курку аркасында да түгеллеген беләсең. Сиңа карата мәхәббәт йөрәгемә кереп утырган. Тик бер хыял-кайгым бар: Йөзеңне күрә алырмын микән!.. Әгәр Сине күрә алачак булсам, һичнәрсәгә борчылмас идем...» – ди.

Җәнабел-Хак вәхидә: «Сүзеңдә тугры булганга күрә, йөземне күрә алу Сиңа насыйп булсын, и, Шөгаеб! Шул сәбәпле Муса ибне Гыймранны сиңа хезмәтче итеп җибәрәм!» – дип белдерә.

Хак Тәгаләгә якын булучыларның хәле әнә шундый. Гафил бәндәләрнең капма-каршысы буларак, алар, барыннан да бигрәк, Аллаһның ризалыгы турында уйлый, халыкның ризалыгы алуны исә иң ахырга калдыралар. Илаһи мәхәббәт йөрәкләрен сарып алганга, дөньяның һәр икесенә (ахирәткә һәм бу дөньяга) хәтта күз чите белән дә карамыйлар.

Аллаһ Тәгалә пәйгамбәрләрне кешеләрнең күңел күзләрен ачып, ваемсызлык йокыларын тарату, аларны күркәм әхлак иясенә әйләндерү, ихлас бирелгәнлек халәтендә гыйбадәт кылып, Аллаһ белән кавыша алуларын тәэмин итү һәм «дарус-сәлам»гә (иминлек урыны, җәннәт) чакыру өчен җибәргән.

Күңел күзе ачылу бәхетенә ирешкән бәндәләр, тәрбияләнү һәм туры юлга чыгарылуны ихлас теләп, Хак Тәгалә юлында алга бару өчен тырышлык куя-

лар. Ләкин мондый изге теләктә булмаганнар, киреләнеп тәкәбберләнгәннәр, пәйгамбәрләренең үгет-нәсыйхәтләренә колак салмаган һәм Аллаһны таныпбелү мәртәбәсенә ирешергә теләмәгәннәр караңгылык һәм кайгы-хәсрәт эчендә калып адашырлар. Кая барачагын белми аптыраган бәндәләрдән һич аерылмыйча, мескен хәлгә калырлар.

Мәрхәмәтенең куәтлелеге аркасында Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәм, кешеләрне аларга янаган авыр хәлдән коткару өчен, гомере буе үзен аямыйча тырышлык куя, бу максатта бөтен көчен сарыф итә.

Мәдйән һәм Әйкә кавемнәренең һәлакәтеннән соң Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәм, гомеренең ахыр көннәрен каршылау өчен, аңа иман китергәннәр белән бергә Мәккәгә һиҗрәт кыла, шунда бакыйлыкка күчә һәм Кәгъбәдәге алтын улак астына, ягъни Хәтим дигән урынга җирләнә.

Галәйһис-сәләәм!..

***Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәм***





ХӘЗРӘТИ

# Муса

*галәйһиссәләм*

*һәм*

ХӘЗРӘТИ

# Харун

*галәйһиссәләм*

***Ахмак фиргавенне Кызыл диңгез чоңгылларында батырган, могҗизалы, затлы***

# ХӘЗРӘТИ МУСА

***галәйһис-сәләәм***

***һәм***

***аңа ярдәмче итеп бирелгән изге кардәше***

# ХӘЗРӘТИ ХАРУН

***галәйһис-сәләәм***

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм – «үлүл-газыйм» пәйгамбәрләрнең өченчесе. Ягъкуб галәйһис-сәләәм нәселе вәкиле, Бәни Исраил пәйгамбәре. Коръәни-Кәримдә исеме иң күп искә алынган пәйгамбәр. Төрле аятьләрдә төрле уңай белән исеме 136 тапкыр телгә алына.

Хәзрәти Йосыф галәйһис-сәләәмне дәүләтенең финанс министры (казна күзәтчесе) итеп куйган Мисыр фиргавеннәреннән Рәййан ибне Мәлик мөэмин була. Аны фиргавен тәхетендә Кабус алыштыра. Бу шәхес Йосыф галәйһис-сәләәмгә иман китерми, ләкин аны вазифасында калдыра. Аннан соң тәхеткә утырган фиргавеннәр исә Бәни Исраил кавемен хөрмәт итми.

Йосыф галәйһис-сәләәмнән соң Исраил угыллары Мисырда кала. Алар Йосыф, Ягъкуб, Исхак һәм Ибраһим галәйһимәс-сәләм дине тарафдары була. Мисырның элек-электән җирле халкы булган кыптыйлар исә мәҗүси булып, йолдызларга һәм потка табына. Кыптыйлар Бәни Исраил кавеменә кимсетеп карыйлар, аларны төрлечә кысрыклыйлар. Фиргавеннәре кансыз һәм явыз кешеләр була. Алар Бәни Исраилнең күбәюенә борчылалар, чөнки сыптыйлар дип йөртелгән Бәни Исраил кавеме зураеп китсә, хакимиятнең шулар кулына күчү мөмкинлеге барлыкка килә.

Бу хәлгә башка түзеп тора алмаган кыптыйлар, беренче чиратта, аларның фиргавеннәре, сыптыйларны кысрыклый, изә башлый. Кыптыйларның көннән-көн арта барган золымына чыдый алмаган сыптыйлар мондый авыр хәлдән шактый арыйлар, тәмам гарык булалар. Алар бу илдә иҗтимагый-сәяси хокукларын тулысынча югалта. Ягъкуб галәйһис-сәләәм төбәге булган Кәнан өлкәсенә китәргә телиләр. Ләкин һич теләкләрен чынга ашыра алмыйлар, чөнки Фиргавен аларны пирамидалар төзелеше кебек авыр хезмәтләрдә эшләтә һәм шуңа күрә аларны җибәрергә теләми.

Унике кабиләдән гыйбарәт Исраил угылларының һәркайсы Ягъкуб галәйһис-сәләамнең берәр улы нәселеннән килә. Фиргавен аларны авыр шартларда эшләтә, җәфалый һәм һәрвакыт кысрыклап, бастырып тота. Эшләрлек хәлдә булмаганнарына көч җитмәслек салымнар билгели, кояш батканчы салымын түләмәгәннәрнең кулларын бәйләтеп, бер ай шул хәлдә йөрттерә. Фиргавеннең бу явызлыклары турында аяти кәримәләрдә болай дип хәбәр ителә:

إِنَّ فِرْعَوْنَ عَلَا فِي الْأَرْضِ وَجَعَلَ أَهْلَهَا شِيَعًا يَسْتَضْعِفُ طَائِفَةً
مِنْهُمْ يُذَبِّحُ أَبْنَاءَهُمْ وَيَسْتَحْيِي نِسَاءَهُمْ إِنَّهُ كَانَ مِنَ الْمُفْسِدِينَ

**«Һичшиксез, фиргавен җирдә (Мисырда) бозыклык кылды һәм аның халкын фиркаләр хәленә китерде, ир балаларын үтереп, хатыннарын исән калдырып, алардан бер төркемне көчсезләндерде. Һичшиксез, ул бозыклык таратучылардан булды»** («әл-Касас», 4).

إِنَّ فِرْعَوْنَ وَهَامَانَ وَجُنُودَهُمَا كَانُوا خَاطِئِينَ

**«...Фиргавен дә, Һаман да, аларның гаскәрләре дә ялгыш эшләгән кешеләр булдылар»** («әл-Касас», 8).

Шушы болгавырлык һәм залимлек чорында Хак Тәгалә Муса галәйһис-сәләамне җибәрә:

وَنُرِيدُ أَنْ نَمُنَّ عَلَى الَّذِينَ اسْتُضْعِفُوا فِي الْأَرْضِ وَنَجْعَلَهُمْ أَئِمَّةً وَنَجْعَلَهُمُ الْوَارِثِينَ.
وَنُمَكِّنَ لَهُمْ فِي الْأَرْضِ وَنُرِيَ فِرْعَوْنَ وَهَامَانَ وَجُنُودَهُمَا مِنْهُمْ مَا كَانُوا يَحْذَرُونَ

**«Әмма Без ул җирдә көчсез хәлгә төшерелгән кешеләргә игелек кылырга, аларны җитәкчеләр итәргә һәм аларны (изге җирләргә) мирасчылар итәргә теләдек. Янә аларга җирдә урнашу мөмкинлеге бирергә, Фиргавенгә, Һаманга һәм аларның гаскәрләренә алар курыккан нәрсәләрен (ул Исраил улларыннан киләчәк дип) күрсәтергә (теләдек)»** («әл-Касас», 5–6).

### Фиргавенне куркыткан төш

Бер төндә Фиргавен шундый төш күрә. Төшендә Иерусалим ягыннан ут килеп чыгып, кыптыйларның өйләрен яндырып бетерә, тик Исраил угылларына бер дә зыян салмый. Тәхет иясе төшен юрата. Аңа: «Бәни Исраил кавеменнән бер бала килеп чыгачак һәм синең бөтен хакимлегеңне, мөлкәтеңне җимерәчәк!» – диләр. Шуннан соң Фиргавен Исраил угылларыннан туасы барлык ир балаларны үтереп барырга боера.

Моның өчен камыштан кораллар ясала, бәбиләр вакыты якынлашкан хатыннарның корсакларын шулар белән кысып, коточкыч газаплар белән аларга вакытыннан алда бала таптыралар. Әгәр дөньяга килгән сабый ир җенесеннән булса, аны шундук суялар.

Риваятькә күрә, Фиргавенне шундый әшәке һәм пычрак гамәлгә этәргән бүтән бер сәбәп түбәндәгечә аңлатыла:

Исраил угыллары үз араларында Хәзрәти Ибраһим нәселеннән бер пәйгамбәр киләчәге һәм Мисыр патшасының (Фиргавеннең) һәлак ителүе аның кулы белән тормышка ашырылачагы турында сөйләшәләр. Бу исә Хәзрәти Ибраһимнең хатыны Сара анабыз белән Фиргавен арасында булган вакыйга белән бәйләп карала. Фиргавен аңа карата явызлык кылырга маташкач, Сара анабызны Аллаһ Тәгалә саклап кала. Димәк, Җәнабел-Хак Ибраһим галәйһис-сәләәм нәселеннән килгән Исраил угылларын да Фиргавен золымыннан коткарачак. Бу сөенечле хәбәр Исраил угыллары арасында тарала, хәтта кыптыйлар да ул хакта искә ала башлый. Вазгыять турында Фиргавенгә җиткерелгәч, ул яраннары белән киңәшләшә дә һәр туган ир баланы үтерергә куша. Шул рәвешле ул үзен һәлак итәчәк баланың үсеп җитәчәгенә комачаулауны максат итеп куя, фәкать мондый чара илаһи тәкъдирне үзгәртә алмый.

Шул чакларда Хәзрәти Ягъкуб нәселеннән булган Гыймранның улы – Хәзрәти Муса дөньяга килә. Кендек әбиләренең берсе Хәзрәти Мусаның туганы була. Муса тугач, аның маңгаенда бик якты нур күреп, ул гаҗәпләнә һәм куркуга кала.

Соңрак, кендек әбиләре бала туганнан соң тышка чыккач, Фиргавен кешеләре өйгә керә. Шул мизгелдә Муса галәйһис-сәләәмнең әнисе, бик борчылып-дулкынланып, сабыен тандыр (мич) эченә яшерә. Гаскәриләр чыгып китүгә үк, бик курка-курка гына, мич капкачын ача. Ни күрсен, нарасые, нәкъ Хәзрәти Ибраһим галәйһис-сәләәм кебек, утның уртасында исән-сау килеш тора. Бик сөенеп, аны шундук кочагына ала һәм Җәнабел-Хакка шөкер итә. Аннары аңа Аллаһтан бер илһам килә; ана кешегә баласын имезергә, куркыныч туганда, аны Нил елгасына ташларга кушыла, баласының үзенә кире кайтарылачагы һәм олуг пәйгамбәр булачагы хәбәр ителә. Аяти кәримәдә болай диелә:

وَأَوْحَيْنَا إِلَى أُمِّ مُوسَى أَنْ أَرْضِعِيهِ فَإِذَا خِفْتِ عَلَيْهِ فَأَلْقِيهِ فِي الْيَمِّ
وَلَا تَخَافِي وَلَا تَحْزَنِي إِنَّا رَادُّوهُ إِلَيْكِ وَجَاعِلُوهُ مِنَ الْمُرْسَلِينَ

**«Һәм Без Мусаның әнисенә: “Син аны имез, әмма әгәр аның өчен курыксаң, аны диңгезгә (Нил елгасына) ташла. Курыкма һәм кайгырма. (Чөнки) һичшиксез, Без аны сиңа кайтарачакбыз, һәм аны пәйгамбәрләрдән берсе итәчәкбез”, – дип илһам иттек»** («әл-Касас», 7).

Шуннан соң Муса галәйһис-сәләәмнең анасы бер балта остасына тиз генә сандык ясата. Муса галәйһис-сәләәмне шуның эченә салып, Нил елгасына ыргыта. Сандыкны ясаган балта остасы бу эшнең асылын аңлый һәм кичекмәстән Фиргавен янына барып, шикаятен сөйләргә маташа. Ләкин теле тотлыга һәм һичнәрсә сөйли алмый. Ахыр чиктә Фиргавен кешеләре аны куып җибәрә.

Сандык Нил буйлап сарай бакчасына агып килә, җарияләр аны табып алып, Асия анабызга китерәләр.

**Хәзрәти Муса Фиргавен сараенда**

Йосыф галәйһис-сәләәмгә иман китергән Мисыр патшасы Рәййан ибне Вәлид нәселеннән Асия Фиргавеннең хатыны була. Бер сандык эчендә аңа китереп бирелгән Мусаны күргәч, күңелендә аңа карата бик көчле мәхәббәт уяна. Бала бик матур була. Асия аны күтәреп, кочагына ала. Аннары Фиргавен янына илтеп: «Бу безнең балабыз булыр, киләчәктә безгә бик күп ярдәме тияр, безне саклар! Моны үтермә! Ул икебезнең дә матур баласы дип саналыр!» – кебек сүзләр белән ирен күндерүгә ирешә.

وَقَالَتِ امْرَأَتُ فِرْعَوْنَ قُرَّتُ عَيْنٍ لِي وَلَكَ لَا تَقْتُلُوهُ عَسَى
أَنْ يَنْفَعَنَا أَوْ نَتَّخِذَهُ وَلَدًا وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ

**«Фиргавеннең хатыны (сандык эченнән ир бала килеп чыккач, иренә): “Минем дә, синең дә күз нурыбыз. Аны үтермәгез! Бәлки, ул безгә файда китерер, яки без аны уллыкка алырбыз”, – диде. Әмма алар (эшнең ахырын) белмиләр иде»** («әл-Касас», 9).

Хәзрәти Мусага сөт анасы эзлиләр. Ләкин бала бер ананы да имми. Муса галәйһис-сәләәмнең апасы Мәрьям әнисенең сөт анасы була алуы турында хәбәр бирә, чөнки әнисе улының кем кулына эләгүен күзәтеп торырга куша:

وَقَالَتْ لِأُخْتِهِ قُصِّيهِ فَبَصُرَتْ بِهِ عَنْ جُنُبٍ وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ. وَحَرَّمْنَا عَلَيْهِ الْمَرَاضِعَ
مِنْ قَبْلُ فَقَالَتْ هَلْ أَدُلُّكُمْ عَلَى أَهْلِ بَيْتٍ يَكْفُلُونَهُ لَكُمْ وَهُمْ لَهُ نَاصِحُونَ

**«(Анасы) Аның (Мусаның) апасына: “Артыннан бар!” – диде. Һәм ул аны (энесен) ерактан күзәтте. Әмма алар белмәделәр. Без алдан (анасына кире кайтарылганчы) имезүче (сөт аналарыннан имүне) аңа тыйдык. Ул (апасы): “Сезнең өчен аны өсләренә (үз җаваплылыкларына) алган һәм аңа игелек теләгән бер йорт халкын сезгә күрсәтимме?” – диде»** («әл-Касас», 11–12).

Сарайда Мусаның апасының тәкъдимен кабул итәләр:

فَرَدَدْنَاهُ إِلَى أُمِّهِ كَيْ تَقَرَّ عَيْنُهَا وَلَا تَحْزَنَ وَلِتَعْلَمَ أَنَّ وَعْدَ اللّٰهِ حَقٌّ وَلَكِنَّ أَكْثَرَهُمْ لَا يَعْلَمُونَ

**«Күңеле тыныч булсын һәм сагышланмасын, янә, һичшиксез, Аллаһның вәгъдәсе хак булганын белсен өчен, Без аны (шул рәвешле) әнисенә кайтардык, ләкин аларның күбесе (моны) белмиләр»** («әл-Касас», 13).

Муса галәйһис-сәләәмнең әнисе Асия анабызның Мусаны имезү турында үтенеченә, шик төшмәсен өчен, шундук ризалашырга ашыкмый. Чөнки бу аятьтәге вәгъдәнең һичшиксез чынга ашачагын белә: «Минем Һарун исемле бер улым бар![118] Шуның белән бергә кабул итсәгез, имезермен, югыйсә, ризалашмыйм!» – дип шарт куя. Шул рәвешле бу хатынның чынлыкта Мусаның әнисе икәнен аңламый калалар һәм акча бәрабәренә Мусага сөтен бирергә кушалар.

Фиргавен белән хатыны Хәзрәти Мусаны уллыкка алырга теләгәндә, аның үзләренең тормыш принциплары нигезендә тәрбияләнеп, үзләренә ияреп-буйсынып үсәр, дип уйлыйлар. Ләкин кеше тормышының формалашуында, чынга ашуында ике әһәмиятле фактор бар – нәселдәнлек һәм тәрбия… Кеше кайчак нәселдәнлек, кайчак тәрбия, кайвакыт исә һәр икесенең тәэсиренә эләгә. Бу хикмәт аяти кәримәдә: «Әмма алар (эшнең ахырын) белмиләр иде!» – рәвешендә, бик нәфис бер өслүп белән белдерелә.

Хәзрәти Мусаны табып үтерү максаты белән, бер риваятькә күрә, Фиргавен – 70000, башка риваятькә күрә исә 100000нән артык гөнаһсыз сабыйның җанын кыйдыра.[119]

Мухйиддин Ибне әл-Гарәби куддисә сирруһ «Фусус әл-Хикәм» исемле әсәрендә, бу вакыйганың хикмәте ягына ишарәләп, мондый аңлатма бирә:

«Дөньяга килергә тиешле Хәзрәти Мусаны юк итү өчен Фиргавен тарафыннан үтертелгән сабыйларның барысы да Хәзрәти Мусага тормышында ярдәмче булу, аның рухи халәтен көчәйтү өчен үтерелгәннәр. Чөнки Фиргавен һәм аның гаиләсе Мусаны әле белмәсәләр дә, аны Хак Тәгалә белә. Әлбәттә, аларның һәркайсының өзелгән гомере Мусаныкына әйләнә. Чөнки төп максат Муса була».[120]

Җәнабел-Хак Хәзрәти Мусаны төп дошманының сараенда үстерә һәм бу бала бервакыт Фиргавенне тәхете һәм мөлкәте белән бергә пыран-заран китерә. Чөнки пәйгамбәрләр шәхсән Аллаһ тарафыннан тәрбияләнә һәм яклана-саклана.

---

118. Исраил улларын кол итеп кулланганга һәм аларны авыр эшләрдә файдаланганга күрә, яңа туган ир балаларны бер елда үтертә, бер елда исән калдыра торган була. Һарун галәйһис-сәләәм әнә шул балалар үтерелмәгән елны дөньяга килә.
119. «Рухул-Бәян», I, 371 («әл-Бәкара» сүрәсендәге 49 нчы аять тәфсирендә).
120. Карагыз: «Фусус әл-Хикәм» тәрҗемәсе һәм шәрехе», IV, 126.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә бер хәдис-шәрифендә болай дип белдерә: *«Мине Раббым тәрбияләде һәм тәрбиямне дә күркәм итте»* (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», I, 12).

Муса галәйһис-сәләәмнең әнисе аны Фиргавен сараенда имезә башлый. Ләкин вәзир Һаман бу хәлдән шикләнә һәм: «Бу бала синекеме әллә?! Чөнки синнән башка һичбер ананың сөтен иммәде, бары синекен генә имде!» – дип әйтә.

Муса галәйһис-сәләәмнең әнисе исә: «Ни дисәң дә, мине бөтен балалар ярата, мин дә аларны яратам», – кебек сүзләр белән Һаманны ышандыра.

Нәтиҗәдә, Мусаның әнисенә даими түләү билгелиләр һәм алтыннар белән бүләкләп, илтифат күрсәтәләр. Бу исә Аллаһның олуг рәхмәте була. Җәнабел-Хак болай ди:

إِنْ كَادَتْ لَتُبْدِي بِهِ لَوْلَا أَنْ رَبَطْنَا عَلَى قَلْبِهَا لِتَكُونَ مِنَ الْمُؤْمِنِينَ

**«Ул (Мусаның әнисе) аны (эшне) ачу дәрәҗәсенә җитте (“Бу – минем улым”, дип әйтеп җибәрәчәк иде). Әгәр дә Без (вәгъдәбезгә) ышанганнардан булуы өчен күңелен куәтләндермәгән булса идек»** («әл-Касас», 10).

Асия анабыз Мусаны сагынган чакта, сөт анасы белән бергә аны сарайга китертеп, бүләкләр белән каршылый торган була. Беркөнне Мусаны Фиргавеннең бүлмәсенә алып киләләр. Фиргавен аны кочагына ала. Муса каты итеп Фиргавеннең сакалын тарта, төген йолкып ала һәм аңа сугып җибәрә (яки Фиргавеннең кулындагы камчыны тартып алып, шуның белән суга). Фиргавен кызып китә: «Менә ул – мин эзләгән дошман!» – ди һәм Мусаны үтерергә карар бирә.

Асия анабыз шундук йөгереп килеп җитә: «Ул бала гына бит! Акылы юк… Теләсәң, сынап карыйк. Бер савыт якут һәм алмазлар, бер савыт ут куйыйк. Әгәр Муса, якутларны алса, акыллы дигән сүз; утны сайласа, бала булып чыга!» – ди ул.

Фиргавен ризалаша. Асылташлар һәм утлы күмерләр салынган ике тәлинкә китертеп, Мусаның алдына куйдыра. Муса галәйһис-сәләәм кулын асылташлар тулы тәлинкәгә сузганда, Аллаһның әмере белән Җәбраил галәйһис-сәләәм моңа каршы чыга һәм кулын читкә этә. Муса утлы күмерне алып, авызына каба. Шунда аның теле янып, сакаулана. Аның бу сакаулыгы Сина тавында дога кылганчыга хәтле саклана.

Баланың утлы күмер кабуын күргән Фиргавен: «Әйе, балалыгы белән шулай эшләгән икән!» – дип, Мусаны гафу итә һәм янә сарайга алдыра.

Аллаһ Тәгалә Муса галәйһис-сәләәмне аның тирәсендәге бөтен кеше тарафыннан яраттыра:

وَأَلْقَيْتُ عَلَيْكَ مَحَبَّةً مِنِّي وَلِتُصْنَعَ عَلَى عَيْنِي

**«(И, Муса!) Мин сиңа Үземнән бер сөю бирдем. Син – Минем күзәтүем астында үстерелүең өчен»** («Та-һә», 39).

Мондый илаһи рәхмәт сәбәпле, Мусаны күргән һәр затның күңелендә аңа карата мәхәббәт уяна торган була. Ниһаять, аңа пәйгамбәрлек бирелә:

وَلَمَّا بَلَغَ أَشُدَّهُ وَاسْتَوَى آتَيْنَاهُ حُكْمًا وَعِلْمًا وَكَذلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ

**«Ул (Муса) җитлегү яшенә җиткәч, Без аңа хөкем һәм гыйлем бирдек. Күркәм гамәл кылучыларга шулай әҗер бирәбез»** («әл-Касас», 14).

Аяти кәримәдә телгә алынган «اَشُدَّهُ» сүзе Муса галәйһис-сәләәмнең физик яктан да, рухи яктан да камиллеккә ирешүен белдерә. Күпләрнең фикеренчә, сүз кырык яшь турында бара. Муса галәйһис-сәләәм шушы яшькә җиткәч, Аллаһ аңа «хөкем» һәм «гыйлем» бирә. «Хикмәт» мәгънәсен дә белдергән «хөкем» сүзе, тәфсирләрдә күпчелек «пәйгамбәрлек» дип тәрҗемә ителә һәм аңлатыла.

Шуннан соң Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм Фиргавеннең дине бозык һәм батыйль икәнлеге турында тәблигъ кыла башлый.

**Кыптыйның үлеме**

Фиргавеннең кыптыйлар кавеменнән Фатун исемле залим икмәк пешерүчесе була. Бу зат беркөнне Самири исемле бер сыптыйны кыйный. Самири Хәзрәти Мусадан ярдәм сорый. Муса галәйһис-сәләәм сугышучыларны аерыр өчен, ике арага керә; Фатунны эткәли-эткәли, сугып җибәрә. Шундый каршылык күрсәтелгәч, Фатун җиргә егылып, җан бирә.

Муса галәйһис-сәләәм бу хәлгә бик борчыла, чөнки аның Фатунны үтерү кебек яшерен максаты булмый. Ул Самиринне генә сакларга тели. Бик нык борчылып, Муса галәйһис-сәләәм Хак Тәгаләгә мөрәҗәгать итә һәм гафу итүен сорый.

Аяти кәримәләрдә бу вакыйга түбәндәгечә аңлатыла:

وَدَخَلَ الْمَدِينَةَ عَلَى حِينِ غَفْلَةٍ مِنْ أَهْلِهَا فَوَجَدَ فِيهَا رَجُلَيْنِ يَقْتَتِلاَنِ
هذَا مِنْ شِيعَتِهِ وَهذَا مِنْ عَدُوِّهِ فَاسْتَغَاثَهُ الَّذِي مِنْ شِيعَتِهِ عَلَى الَّذِي مِنْ عَدُوِّهِ فَوَكَزَهُ
مُوسَى فَقَضَى عَلَيْهِ قَالَ هَذَا مِنْ عَمَلِ الشَّيْطَانِ إِنَّهُ عَدُوٌّ مُضِلٌّ مُبِينٌ

**«Халкының гафләт хәлендә булган чагында ул (Муса) шәһәргә керде дә, анда бер-берсе белән сугышкан ике кешегә юлыкты. Берсе аның каве-**

**меннән, икенчесе исә аның дошманнарыннан иде. Үз тарафдарларыннан булган кеше дошманнарыннан булган кешегә каршы аңардан ярдәм сорады. Муса аңа йодрыгы белән сукты да үтерде. (Шуннан соң) әйтте: "Бу – шайтанның эшләреннән. Һичшиксез, ул – ап-ачык юлдан яздыручы дошман"»** («әл-Касас», 15).

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләам һәр җирдә тәүхид дингә өндәп йөри башлагач, кешеләргә хакыйкатьне белдергән өчен, Фиргавеннең кыптыйлары аңа каршы чыга. Шунлыктан Муса галәйһис-сәләам халык өйләренә таралышкач кына, шәһәргә керә. «Бу – шайтанның эшләреннән!» дигәндә, галимнәр фикеренчә, Хәзрәти Муса үзе кылган гамәлгә түгел, ә хаклы рәвештә үлем җәзасын алган, үтерелгән затка ишарәли. Шул ук вакытта, аны үтерергә, дигән әмер алмаганга күрә, Хәзрәти Мусаның бу сүзләр белән үзен күздә тотуы да белдерелә. Ләкин аның һич мондый максаты булмый:

قَالَ رَبِّ إِنِّي ظَلَمْتُ نَفْسِي فَاغْفِرْ لِي فَغَفَرَ لَهُ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ.
قَالَ رَبِّ بِمَا أَنْعَمْتَ عَلَيَّ فَلَنْ أَكُونَ ظَهِيرًا لِلْمُجْرِمِينَ

**«Ул (Муса): "И, Раббым! Мин үз-үземә золым эшләдем, мине ярлыка!" – диде. Ул аны гафу итте. Һичшиксез, Ул – Гафу итүче, Рәхимле. (Муса) әйтте: "И, Раббым! Мине нигъмәтләндергәнең өчен, гөнаһлылар (һәм гөнаһка тартучылар) яклы булмаячакмын"»** («әл-Касас», 16–17).

Бу вакытта кыптыйлар, үтерелгән кыптыйның үтерүчесен табар өчен, Фиргавенгә шикаять белдерәләр. Фиргавен аның үтерелүенә кагылышлы шаһит таләп итә. Бертөрле дә шаһит та табып китермиләр. Шуннан соң Фиргавен, җан кыючыны эзләп, шәһәрдән читкә чыга.

Икенче көнне Хәзрәти Муса шул ук сыптыйны башка бер кыптый белән сугышкан хәлдә очрата. Сыптый Муса галәйһис-сәләамнән тагын ярдәм сорый. Муса исә: «Синең аркада нәфесемә золым кылдым!» – ди.

Бу сүзне ишеткәч, шундагы бер кыптый кичемәстән Фиргавен янына йөгерә һәм Хәзрәти Мусадан зарланып: «Сезнең икмәкчегез Фатунны Муса үтерде!» – ди. Фиргавен гаеплене үлем белән җәзалау турында карар бирә.[121] Бу хакта Фиргавеннең агасының улы Муса галәйһис-сәләамгә яшерен рәвештә хәбәр итә, чөнки ул Хәзрәти Мусага иман китергәннәрнең берсе була.

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләамнең кыптыйны үтереп, ярлыкау өчен Раббысына ялварганнан соңгы хәле аяти кәримәләрдә түбәндәгечә бәян ителә:

121. Фәхри Разый аңлатканча, Муса галәйһис-сәләам кыптыйны үтерергә теләми. Икенче яктан карaганда, кыптый бер мөшрик бәндә була, шунлыктан җәза тиеш тә түгел. Шул ук вакытта бу вакыйга ялгышлык аркасында килеп чыкканга күрә дә, җәза турында сүз бара алмый.

فَأَصْبَحَ فِي الْمَدِينَةِ خَائِفًا يَتَرَقَّبُ فَإِذَا الَّذِي اسْتَنْصَرَهُ بِالْأَمْسِ يَسْتَصْرِخُهُ قَالَ لَهُ مُوسَى إِنَّكَ لَغَوِيٌّ مُبِينٌ. فَلَمَّا أَنْ أَرَادَ أَنْ يَبْطِشَ بِالَّذِي هُوَ عَدُوٌّ لَهُمَا قَالَ يَا مُوسَى أَتُرِيدُ أَنْ تَقْتُلَنِي كَمَا قَتَلْتَ نَفْسًا بِالْأَمْسِ إِنْ تُرِيدُ إِلَّا أَنْ تَكُونَ جَبَّارًا فِي الْأَرْضِ وَمَا تُرِيدُ أَنْ تَكُونَ مِنَ الْمُصْلِحِينَ.

**«Ул (Муса) курку эчендә иртән шәһәрдә (тирә-ягын күзәтеп) көткән берәү хәленә килде. Кинәт кичә аңардан ярдәм сораган кеше, кычкырып, аңардан ярдәм сорады. Муса аңа әйтте: “Һичшиксез, син – ап-ачык азгынсың”. Ул (Муса) икесенә дә дошман булган кешене тотып алырга теләгәч: “И, Муса! Кичә бер кешене үтергәнең кебек мине үтермәкче буласыңмы? Син җирдә җәберләүче булырга телисең, әмма төзәтергә тырышучылардан булырга теләмисең!” – диде»** («әл-Касас», 18–19).

Шул заман:

وَجَاءَ رَجُلٌ مِنْ أَقْصَى الْمَدِينَةِ يَسْعَى قَالَ يَا مُوسَى إِنَّ الْمَلَأَ يَأْتَمِرُونَ بِكَ لِيَقْتُلُوكَ فَاخْرُجْ إِنِّي لَكَ مِنَ النَّاصِحِينَ. فَخَرَجَ مِنْهَا خَائِفًا يَتَرَقَّبُ قَالَ رَبِّ نَجِّنِي مِنَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ

**«Бер кеше шәһәрнең читеннән йөгерә-йөгерә килде дә: “И, Муса! Олуглар сине үтерергә дип, синең хакта киңәшләшә. (Хәзер үк моннан) кит! Һичшиксез, мин сиңа игелек теләүчеләрдәнмен”, – диде. Куркулы бер хәлдә ул (Муса), карана-карана, аннан чыкты һәм: “И, Раббым! Бу залимнәр кавеменнән мине коткар”, – диде»** («әл-Касас», 20–21).

Муса галәйһис-сәләәм үз-үзен шулай тотышы, шулай гамәл кылуы белән Аллаһка чын буйсынучанлыкның нинди булырга тиешлеген дә күрсәтә: иң әүвәл киңәшү, аннары ният (карар), соңыннан чара (гамәл) һәм нәтиҗәне Аллаһка тапшыру (дога һәм язмышка буйсыну). Менә ул чын буйсыну, үзеңне Аллаһка багышлау!..

### Мисырдан Мәдйәнгә

Муса галәйһис-сәләәм кичекмәстән Мәдйәнгә таба юлга кузгала. Чынлыкта ул моңарчы беркайчан да шәһәрдән чыкмый һәм кайсы якка барырга кирәклеген дә белми. Хәтта үзе белән ашарга ризык та алмаган була. Аллаһ Тәгалә аның янына Җәбраил галәйһис-сәләәмне җибәреп, Мәдйән юлын күрсәтә. Мәдйән ул чорда Мисырдан сигез көнлек сәфәр ераклыгында була.

وَلَمَّا تَوَجَّهَ تِلْقَاءَ مَدْيَنَ قَالَ عَسَى رَبِّي أَنْ يَهْدِيَنِي سَوَاءَ السَّبِيلِ

**«Мәдйән тарафына юнәлгәч: “Бәлки, Раббым мине юлның турысына чыгарыр”, – диде»** («әл-Касас», 22).

Мәдйән халкы белән Муса галәйһис-сәләәм арасында туганлык булганлыгы риваять кылына. Чөнки мәдйәнлеләр дә, Хәзрәти Муса да Ибраһим галәйһис-сәләәм нәселеннән килә. Хәтта Ибраһим галәйһис-сәләәмнең бер улы да Мәдйән исемле була. Бу шәһәр Фиргавенгә буйсынмый.

Ниһаять, Муса галәйһис-сәләәм Мәдйәнгә килеп җитә. Халык Мәдйән кальгасыннан көтүләрен чыгарган чакка туры килә. Хәзрәти Муса туктаган урында бер кое була. Һәм шәһәрдән чыккан көтүләр шуңа таба юнәлә. Бераздан һәркем, сарыкларын эчерү өчен, кое тирәсенә җыела. Ләкин Хәзрәти Муса ике хатын-кызның сарыклары белән бергә читтә торуларын һәм халык арасына кысылмауларын күреп ала һәм бу анда кызыксыну уята. Ул бу ханымнардан: «Сез ни көтәсез? Ник терлекләрегезне эчермисез?» – дип сорый. Теге хатын-кызлар: «Көтүчеләр китмичә, хайваннарыбызны эчертә алмыйбыз!» – дип җавап бирәләр.

Муса галәйһис-сәләәм: «Һичкемегез, якыннарыгыз юкмы?» – дип белешә. «Әтиебез бик карт һәм хәлсез, шунлыктан сарыкларны эчертү, утлату-ашату кебек эшләр безнең өскә кала. Ир-атлар арасына керергә теләмәгәнгә, алар коедан киткәч кенә, көтүләребезгә су бирәбез. Әмма алар башта эчергәч, кайчак коеда су бетеп китә, хайваннарыбызны эчертә алмый калабыз!» – дип сөйләп бирәләр.

Аяти кәримәдә болай дип аңлатыла:

وَلَمَّا وَرَدَ مَاءَ مَدْيَنَ وَجَدَ عَلَيْهِ أُمَّةً مِنَ النَّاسِ يَسْقُونَ وَوَجَدَ مِنْ دُونِهِمُ امْرَأَتَيْنِ
تَذُودَانِ قَالَ مَا خَطْبُكُمَا قَالَتَا لَا نَسْقِي حَتَّى يُصْدِرَ الرِّعَاءُ وَأَبُونَا شَيْخٌ كَبِيرٌ

**«Мәдйән суы барып җиткәч, (Муса) анда төрле кешеләр төркеме тапты, алар (терлекләрен) су эчерәләр иде. Алардан түбәндәрәк исә ике хатынны тапты, алар (терлекләрен судан) куып торалар иде. Ул: “Сез икәү ни телисез?” – диде. Ул икәү: “Көтүчеләр (хайваннарны эчереп) киткәнче, без (суга кереп, терлекләребезне) эчермибез, атабыз исә бик карт инде”, – диделәр»** («әл-Касас», 23).

Болар Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәмнең кызлары Сафура белән Сүфәйра була. Муса галәйһис-сәләәм, сигез көн тирәсе ач йөрүенә карамастан, көч-хәл белән булса да, коедан су чыгарып, Сафура белән Сүфәйраның терлекләрен эчерә. Хатын-кызлар, рәхмәт әйтеп, үз юллары белән китеп бара.

فَسَقَى لَهُمَا ثُمَّ تَوَلَّى إِلَى الظِّلِّ فَقَالَ رَبِّ إِنِّي لِمَا أَنْزَلْتَ إِلَيَّ مِنْ خَيْرٍ فَقِيرٌ

**«Ул (Муса) икесе өчен (сарыкларын) эчерде, шуннан соң күләгәгә кайтты һәм: “И, Раббым! Мин хәердән Син миңа индергән нәрсәгә мохтаҗмын”, – диде»** («әл-Касас», 24).

Муса галәйһис-сәләам ничә көн берни дә ашамаган була, бик ачыга. Югарыдагы сүзләре белән ул Раббысыннан үзенә азык бирүен үтенә. Аятьнең икенче җөмләсен: «Чынлыкта, миңа иңдергән хәерле нәрсә аркасында мохтаҗмын!» мәгънәсендә дә аңлаталар. Бу фикергә ярашлы рәвештә, Муса галәйһис-сәләам үзенә йөкләнгән олуг вазифага һәм дөньялыкта фәкыйрь калуына ишарә ясый. Чөнки ул Фиргавен янында вакытта муллыкта гомер кичерә. Әмма югарыдагы сүзләрне ниндидер шикаять түгел, ә аны иминлеккә ирештергән өчен, Җәнабел-Хакка шөкер итү һәм аның ачлыктан коткару өчен ялвару буларак кабул итү тиеш.

Шөгаеб галәйһис-сәләам кызларының сарыкларны бик тиз эчереп кайтуларын күргәч, гаҗәпләнеп, моның сәбәбе белән кызыксына. Кызлары исә бу шәһәрдә моңарчы һич күренмәгән бер изге бәндәнең аларга ярдәм итүе турында сөйләп бирә.

**Шөгаеб галәйһис-сәләамнең Хәзрәти Мусаны үз янына чакыруы**

Шөгаеб галәйһис-сәләам Муса галәйһис-сәләамне үз янына чакырта һәм аның кем булуы турында сораштыра. Муса галәйһис-сәләам: «Мин Ягъкуб галәйһис-сәләам нәселеннән Гыйммран улы Муса булам», – дип, үз башыннан кичкәннәрне бәян кыла. Шөгаеб галәйһис-сәләам: «Курыкма! Монда Фиргавен хөкеме үтмәс!» – дип тынычландыра.

Аяти кәримәдә бу хакта болай диелә:

فَجَاءَتْهُ إِحْدَيهُمَا تَمْشِي عَلَى اسْتِحْيَاءٍ قَالَتْ إِنَّ أَبِي يَدْعُوكَ لِيَجْزِيَكَ أَجْرَ مَا سَقَيْتَ
لَنَا فَلَمَّا جَاءَهُ وَقَصَّ عَلَيْهِ الْقَصَصَ قَالَ لَا تَخَفْ نَجَوْتَ مِنَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ

**«Икесеннән (ул хатыннардан) берсе оялып кына килде һәм: “Безнең өчен (терлекләрне) эчергәнеңнең хакын бирергә, дип, әтием сине чакыра”, – диде. (Муса) аңа килгәч һәм вакыйганы сөйләп биргәч, ул (Шөгаеб): “Курыкма. Ул залимнәр кавеменнән котылдың”, – диде»** («әл-Касас», 25).

Шөгаеб галәйһис-сәләам ризык тәкъдим итә. Хәзрәти Муса шулкадәр ач булуына карамастан, ризыкка үрелергә кыймый тора. Шөгаеб галәйһис-сәләам моның сәбәбен сорый. Муса галәйһис-сәләам: «Без шундый гаиләдән ки, бөтен дөньяны бирсәләр дә, аны бер ахирәт гамәленә алыштырмыйбыз! Мин бу ризык өчен түгел, Аллаһ ризалыгы өчен булыштым», – дип белдерә. «Әлеге сыебыз ярдәмең өчен түгел, кунагыбыз булганың өчен, әйдә, авыз ит!» – ди Шөгаеб галәйһис-сәләам.

Бик арыган һәм ачыккан Хәзрәти Муса галәйһис-сәләам шуннан соң гына ашый башлый һәм хәл җыю өчен ял итә.

Сафура әтисенә бу кешене күпмедер хак бәрабәренә яшәтеп торырга киңәш бирә:

قَالَتْ إِحْدَيهُمَا يَا أَبَتِ اسْتَأْجِرْهُ إِنَّ خَيْرَ مَنِ اسْتَأْجَرْتَ الْقَوِيُّ الْأَمِينُ

**«Икесеннән (Шөгаебнең ике кызыннан) берсе: “И, әтием! Син аны (көтүче итеп) ялла, ул бит ялланган кешеләреңнән иң яхшысы, көчле һәм ышанычлы”, – диде»** («әл-Касас», 26). Һәм өстәп куя: «Мондый сыйфатлар менә бу кешедә бар, чөнки ул йөзебезгә дә күтәрелеп карамады. Юлда чакта да бик читтән бара иде. Бик ышанычлы кеше икәне аңлашыла булыр!»

Бу аятьтә теге яки бу вазифа йөкләнергә тиешле кешедә булырга тиеш сыйфатлар шулкадәр күркәм рәвештә белдерелгән:

1. Лаеклык: эш рәтен белү һәм шул ук вакытта ул эшне уңышлы башкарып чыгарлык көч-куәткә ия булу;

2. Ышанычлылык: тугры һәм аңа таянырлык, ышанырлык зат булу.

«Гараисүл-Мәҗалис» исемле китапта тапшырылган риваятьтә болай диелә:

«Зирәклек ягыннан хатын-кызларның икесе аеруча өстен тора. Аларның икесе дә Хәзрәти Муса хакындагы бәяләмәләрендә зирәклек белән эш йөрткәннәр. Беренчесе Фиргавеннең хатыны Асия була. (Муса бер сандык эчендә сарайга китерелгәч, аңа күңел биреп, баланы Фиргавенгә алып бара һәм:) “Бу бала синең һәм минем өчен күз нуры, көн яктысы булсын! Аны үтермә!” – дип әйтә. Икенчесе исә Шөгаеб галәйһис-сәләамнең кызы. “Әткәем! Син аны сарыкларыбызны көтәр өчен ялла! Ул яллап эшләткән кешеләреңнән иң яхшысы, көчле һәм ышанычлы!” – дип әйтә».

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезнең мондый хәдисе риваять кылына: *«...Шөгаеб галәйһис-сәләәм кызына: “Кызым, аның көчле икәнен каян белдең?” – дип сорады. Кызы: “Бер авыр ташны кое өстенә күтәреп куйды”, – диде. Шөгаеб галәйһис-сәләәм: ”Ярар, ә ышанычлы булганын ничек белдең?” – дип сорады. Кызы: “Аны синең исемнән чакырып, монда алып килгәндә, миңа, артымнан бар, алдымнан барма, дип әйтте. Бу сүзләреннән мин аның ышанычлы кеше икәнен аңладым”, – дип җавап бирде»* (Хәйсәми, VIII, 203–204).

Зирәклек, үткенлек – изге мөэминнәрдә барлыкка килә торган алдан күрүчәнлек тойгысы, яшеренне сизү халәте ул. Ягъни акыллылык, төплелек, үтә күрүчәнлек дигәнне белдергән зирәклек йөрәктә урын ала торган рухи аңлау, танып белү дәрәҗәсенә тиң.

Хәзрәти Госман радыйаллаһу ганһе күзе хәрәмгә төшкән берәүне күргәч, аңа: «Күзеңне хәрәмнән сакла!» – дип боера. Теге кеше исә: «Йә, хәлифә!

Күземнең хәрәмгә караганын каян белдең?» – дип сорагач, Хәзрәти Госман радыйаллаһу ганһе: «Мөэминнең зирәклегеннән сакланыгыз! Чөнки ул Аллаһның нуры белән карый!..» – дигән хәдисне искә ала (Тирмизи, «Тәфсир», 15).

Әбү Хәнифә тәһарәт алып торган бер егетне күргәч: «Менә шундый-шундый ялгышлыклар җибәрмә!» – дип кисәтә. Теге егет, гаҗәпкә калып, имамга: «Йә, имам! Мондый ялгышлар җибәргәнемне каян белдегез?» – дип сорый, Әбү Хәнифә хәзрәтләре исә: «Тәһарәт (вакытында пакьләнә торган) әгъзалардан аккан сулардан!» – дип белдерә.

Хәзрәти Хәдичә, Хәзрәти Гайшә һәм Хәзрәти Фатыйма радыйаллаһу ганһүннә дә зирәклеккә ия аналарыбыз санала. Хәдичә анабыз малын һәм җанын Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә багышлаган һәм Аның пәйгамбәрлеген беренче булып раслаган зат дәрәҗәсенә лаек табыла. Хәзрәти Гайшә анабыз исә Рәсүлүллаһны аңлау, Аны камил рәвештә төшенү, танып белү сәләтенә һәм пәйгамбәрләргә хас әдәп-әхлак үрнәген белдергән тирән хиселлек һәм сизгерлеккә ия була. Фатыйма анабызга атасыннан мәрхәмәт, шәфкать һәм тәкъвалык халәте күчә. Шул рәвешле бер яктан караганда, һәркайсының уртак сыйфатлары булса да, икенче яктан караганда, һәркайсында сирәк очрый торган төрле-төрле үзенчәлекләр чагылыш таба.

Хәләл ризык белән туклану һәм күңел хәятен үстерү зирәклекнең шарты булып тора. Васытый радыйаллаһу ганһе: «Зирәклек – йөрәк чәчеп торган нурның яктысы ул. Йөрәккә кереп урнашкан мәгърифәт ул (ягъни Җәнабел-Хакны күңел белән танып белү, күңел белән аңлый белү һәм Аңа якыная алу). Бу мәгърифәт ярдәмендә яшерен серләр ачылыр…» – дип аңлата.

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ үзенең «Мәснәви»ендә мәгърифәт серенә мондый ачыклык кертә:

«Акыл дөньялыктагы эшләребездә уңышка китерүенә карамастан, аның көч-сәләте хакыйкатькә, илаһи серләргә, ягъни мәгърифәтуллаһка ирешүдә җитәрлек булмас. Мондый олуг сәфәр өчен башка чара кирәк. Ул да булса – күңел, мәхәббәт, тәмам бирелгәнлек, рухият дөньясына чуму. Акыл Мостафага корбан булсын!»

Әүлиялардан Габделхалик Гуҗдүвани хәзрәтләре белән бер әңгәмәгә килгән чит егет: *«Мөэминнең зирәклегеннән сакланыгыз! Чөнки ул Аллаһның нуры белән карый!»* хәдисенең (Тирмизи, «Тәфсир», 15) сере нидә?» – дип сорый. Габделхалик Гуҗдүвани хәзрәтләре җавабында әйтә: «Билеңдәге зүннарны[122] чишеп ташла! (христианнар тага торган ул көферлек галәмәтен сүт!) Һәм исламга кил!..»

Мондый зирәклек, үтә күрүчәнлек, илаһи рәхмәт каршында егет остаз алдында шәһадәт кәлимәсен әйтеп, мөселман була. Шуннан соң Хәзрәти

122. Христиан дин әһелләренең билләренә бәйли торган үрелгән билбау.

Гүждүвани тарикатендәге шәкертләренә, тарафдарларына: «Без дә йөрәкләребездәге зүннарны чыгарып ташлыйк!» – дип мөрәҗәгать итә.

Йөрәктәге зүннарны тәкәбберлек, горурлык, хөсетлек, саранлык һәм көнчелек кебек күңелгә кереп оялаган яман әхлак дип карарга мөмкин.

**Муса галәйһис-сәләамнең Сафура белән өйләнешүе**

Шөгаеб галәйһис-сәләам Хәзрәти Мусаны бик ошата һәм аны үз янында калдырырга тели. Моның берәр җаен эзли һәм Сафурага өйләнергә тәкъдим итә. Муса галәйһис-сәләам үзенең ничек өйләнә алачагын сорый, чөнки һич мал-мөлкәте булмый. Шөгаеб галәйһис-сәләам, сигез ел сарыкларын көтү шарты белән, кызын хатынлыкка ала алачагын белдерә, ә ун ел булса, тагын да яхшырак икәнен өстәп куя. Бу сүзнең максаты исә Хәзрәти Мусаны тагын да озаграк вакытка үзе янында тотудан гыйбарәт була. Әлеге әңгәмә Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә тасвирлана:

قَالَ إِنِّي أُرِيدُ أَنْ أُنْكِحَكَ إِحْدَى ابْنَتَيَّ هَاتَيْنِ عَلَى أَنْ تَأْجُرَنِي
ثَمَانِيَ حِجَجٍ فَإِنْ أَتْمَمْتَ عَشْرًا فَمِنْ عِنْدِكَ وَمَا أُرِيدُ أَنْ أَشُقَّ
عَلَيْكَ سَتَجِدُنِي إِنْ شَاءَ اللَّهُ مِنَ الصَّالِحِينَ

**«Ул (Шөгаеб): “Һичшиксез, мин синең миңа сигез ел яллануың бәрабәренә шушы кызларымның берсен сиңа никахларга телим. Әгәр дә унга тутырсаң, синең үзеңнән (бер рәхмәт булыр). Минем Сиңа авырлык тудырасым килми, иншә Аллаһ, тиздән син мине изге кешеләрдән табачаксың”, – диде»** («әл-Касас», 27).

قَالَ ذَلِكَ بَيْنِي وَبَيْنَكَ أَيَّمَا الْأَجَلَيْنِ قَضَيْتُ فَلَا عُدْوَانَ عَلَيَّ وَاللَّهُ عَلَى مَا نَقُولُ وَكِيلٌ

**«Ул (Муса): “Бу – минем белән синең арада. Ул ике вакытның кайсын тутырсам да, миңа карата хаксызлык (тою) булмас. Аллаһ бит сөйләгән нәрсәләребезгә Яклаучы”, – диде»** («әл-Касас», 28).

Әлеге аяти кәримәдә иҗтимагый тормышта еш очрый торган бер мәсьәләгә игътибар юнәлтелә. Кешеләрнең иң ышанычлылары булган ике пәйгамбәр дә, берәр эш турында килешкәндә, киләчәктә килеп чыгуы ихтимал төрле хәлләрне дә онытмыйча, баштан ук һәрнәрсәне ачыктан-ачык сөйләшеп, уртак карарда искә алганнар. Иң ахырда гына Аллаһка тәвәккәл кылып, Аны бу килешүләренең шаһиты итеп санаганнар. Бу очракта да, алдан килешкәнчә, Муса галәйһис-сәләам Шөгаеб галәйһис-сәләамнең малларын көтү шарты белән хезмәткә керешә.

Риваятькә күрә, Муса галәйһис-сәләам сарыкларны көткәндә, һичберсенә таяк белән сукмый, аларны рәнҗетми, ач калдырмый. Аллаһ Тәгалә исә аны

Исраил угылларына пәйгамбәр итеп җибәрә, аның белән бу хакта сөйләшә. Пәйгамбәрлек вазифасы йөкләнгәч тә, Муса галәйһис-сәләәм көтүчелек эшен туктатмый һәм халкын бик күп яманлыклардан саклый.

Аллаһның мәхлукларына карата шәфкатьле мөгамәлә күрсәтмәгән зат Аллаһның дусты була алмый. Ул яралткан нәрсәләрне иркәләсә-сөйсә, аларга шәфкатьле мөгамәлә сакласа, бәндә тәкъва затлар ирешә торган дәрәҗәләргә лаек булыр.

Көтүчелек бөтен пәйгамбәрләр дә диярлек азмы-күпме шөгыльләнгән һөнәр санала. Шул рәвешле Аллаһ, тәблигъ вазифасын йөкләгәнчә, аларда җаваплылык, вазифаны җиренә җиткереп башкару хисе, шәфкать һәм мәрхәмәт кебек идарә итү эшендә таләп ителгән күп кенә сыйфатларны тәрбияли.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Муса галәйһис-сәләәмгә, сарыкларын эчерергә теләгән вакытта, шул җирдә таягы белән сугып су чыгару сәләте бирә. Әнә шундый илаһи нигъмәт ярдәме белән Хәзрәти Муса терлек-туарларын эчерүдә кыенлык кичерми.

Ниһаять, Муса галәйһис-сәләәм көтүчелек хезмәтендә сигез елны тутыра. Хәзрәти Шөгаеб галәйһис-сәләәм сарыкларын кияве белән кызына бүләк итеп бирә. Ләкин Муса галәйһис-сәләәм бу хезмәтен унынчы елда да дәвам итә.[123] Кешеләргә аеруча ошый торган чуар бәрәннәр башка ел аз санда туа торган була, унынчы елда исә сарыкларның барысы да чуар төстәге игез бәрән китерә. Шөгаеб галәйһис-сәләәм: «Бу – Аллаһтан Муса гаиләсенә бер сый-нигъмәт!» – дип әйтә.

### Муса галәйһис-сәләәм таягы

Сарыкларын ерткыч хайваннардан саклар өчен, Муса галәйһис-сәләәм кулына таяк тотып йөри. Таякның бер башы тотар өчен җайлана, ә икенче башы очлы була. Бу таякның каян чыкканлыгы турында төрле риваятьләр бар.

Бер риваятькә күрә, ул таяк Адәм галәйһис-сәләәмнән Шөгаеб галәйһис-сәләәмгә кадәр кулдан-кулга күчеп килгән. Шөгаеб галәйһис-сәләәм исә, сарыкларын көтсен өчен, аны Хәзрәти Мусага тапшырган.

Бу тирәнең уң ягы – таулык, сул ягы көтүлек була. Тау тарафында кыргый хайваннар яши, алар сарыкларга һөҗүм итә ала. Шуңа күрә Муса галәйһис-сәләәм таягын һич үзеннән калдырмый. Хәзрәти Муса таяк белән бәйле берничә күренешнең шаһиты була, әйтерсең, ул вакыйгалар таякка бәйле олуг могҗизага әзерли.

123. Карагыз: Һәйсәми, VIII, 203.

**Мәдйәннән Мисырга бару һәм Тува үзәнлеге**

Унъеллык срок тулганнан соң, Муса галәйһис-сәләәм, Шөгаеб галәйһис-сәләәмнән рөхсәт алып, хатыны Сафура белән бергә Мисырга кайтырга карар бирә. Сарыкларын да үзләре белән алып, кыш көне юлга кузгалалар. Хәзрәти Муса, кардәше Һарунны да үз янына дәшеп, Исраил угылларын аларны гел җәберләп торган Мисырдан читкә чыгару максатын күздә тота.

Юлда чакта бик көчле яңгырга эләгәләр. Кышкы кич. Күзгә төртсәң дә күренми торган караңгылык. Төн уздыру өчен, бәрәкәтле Сина тавына килеп, шундагы бер мәгарәгә сыеналар. Муса галәйһис-сәләәмнең хатыны йөкле була, бик тиздән сабыйлары дөньяга килергә тиеш чак. Бу салкын, караңгы, яңгырлы төндә алар утка һәм яктылыкка мохтаҗ була. Хәзрәти Муса чакма ташын бәреп ут элдерергә маташа, ләкин кабыза алмый. Шундый авыр чакта ул еракта якты ут күрә. Гаиләсенә шуннан ут алып кайтачагын белдереп, бу җирдән беркая да китмәскә куша. Чынлыкта, ул күргән ут аны пәйгамбәрлеккә хәзерләү өчен бер билге була. Аяти кәримәләрдә болай дип белдерелә:

فَلَمَّا قَضَى مُوسَى الْأَجَلَ وَسَارَ بِأَهْلِهِ آنَسَ مِنْ جَانِبِ الطُّورِ نَارًا قَالَ لِأَهْلِهِ امْكُثُوا
إِنِّي آنَسْتُ نَارًا لَعَلِّي آتِيكُمْ مِنْهَا بِخَبَرٍ أَوْ جَذْوَةٍ مِنَ النَّارِ لَعَلَّكُمْ تَصْطَلُونَ

**«Муса вакытын тутырып, гаиләсе белән бергә юлга чыккач, Тур тарафыннан бер ут күрде дә гаиләсенә: “Көтеп торыгыз (монда). Мин бер ут күрдем. Бәлки, шуннан сезгә бер хәбәр китерермен яки сезгә җылыныр өчен, утлы кисәү алып килермен”, – диде»** («әл-Касас», 29).

وَهَلْ أَتَاكَ حَدِيثُ مُوسَى. إِذْ رَأَى نَارًا فَقَالَ لِأَهْلِهِ امْكُثُوا إِنِّي آنَسْتُ
نَارًا لَعَلِّي آتِيكُمْ مِنْهَا بِقَبَسٍ أَوْ أَجِدُ عَلَى النَّارِ هُدًى

**«(Рәсүлем!) Сиңа Муса турында хәбәр ирештеме? Менә ул бер ут күрде һәм гаиләсенә: “Шунда торып торыгыз, мин бер ут күрдем. Бәлки мин сезгә утлы кисәү белән килермен яки ул ут янында юл өйрәтүчеләрне табармын”, – дигән иде»** («Та-һә», 9–10).

Муса галәйһис-сәләәм яктылыкка таба бара. Анда барып җиткәч, яшел агач өстендә яктылык чәчеп торган нур көлтәсен күрә.

فَلَمَّا أَتَاهَا نُودِي مِنْ شَاطِئِ الْوَادِي الْأَيْمَنِ فِي الْبُقْعَةِ الْمُبَارَكَةِ
مِنَ الشَّجَرَةِ أَنْ يَا مُوسَى إِنِّي أَنَا اللهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ

**«Анда килгәч, мөбәрәк җирдәге үзәнлекнең уң тарафыннан, (андагы) агачтан болай дип мөрәҗәгать кылынды: “И, Муса! Һичшиксез, (шуны бел) Мин бөтен галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһ!”»** («әл-Касас», 30).

فَلَمَّا أَتَاهَا نُودِيَ يَا مُوسَى. إِنِّي أَنَا رَبُّكَ فَاخْلَعْ نَعْلَيْكَ إِنَّكَ بِالْوَادِ الْمُقَدَّسِ طُوًى. وَأَنَا اخْتَرْتُكَ فَاسْتَمِعْ لِمَا يُوحَى. إِنَّنِي أَنَا اللّٰهُ لَا إِلَهَ إِلَّا أَنَا فَاعْبُدْنِي وَأَقِمِ الصَّلوٰةَ لِذِكْرِي. إِنَّ السَّاعَةَ اٰتِيَةٌ أَكَادُ أُخْفِيهَا لِتُجْزَى كُلُّ نَفْسٍ بِمَا تَسْعَى. فَلَا يَصُدَّنَّكَ عَنْهَا مَنْ لَا يُؤْمِنُ بِهَا وَاتَّبَعَ هَوَاهُ فَتَرْدَى

**«Ул анда баргач (Безнең тарафтан): “И, Муса!” дигән тавыш килде. Һичшиксез, Мин – синең Раббың! Аяк киемнәреңне (нагълиннәреңне) сал! Син – мөкатдәс Тува үзәнлегендә. Мин сине сайладым, вәхи ителәчәк нәрсәләрне яхшы тыңла. Һичшиксез, Мин – (бердәнбер) Аллаһ, Миннән башка һичбер илаһ юк. Миңа гына гыйбадәт кыл, намазны да Мине искә төшерер өчен укы. Һәркем тырышкан гамәленең әҗерен алсын, дип, һичшиксез, сәгать (Кыямәт көне) киләчәк. Мин аны яшерергә телим. Аңа ышанмаган һәм начар теләкләренә төшкән (затлар) сине алардан тыймасын, югыйсә, соңыннан һәлак булырсың!»** («Та-һә», 11–16).

Мөфәссирләр, аяти кәримәдәге «Нагълиннәреңне сал!» сүзтезмәсенә төрлечә аңлатма биреп, ишари тәфсир аша яшерен мәгънәләрне ачарга тырышалар.[124] Бу сүзләр Кушәйринең «Ләтаиф әл-Ишарат» һәм Бурсәвинең «Рухул-Бәян» исемле хезмәтләрендә түбәндегечә аңлатыла:

«Ике нагълин дөньялык белән ахирәтне белдерә».

«Йөрәкне бу дөнья һәм ахирәт белән бәйле эш-шөгыльләрдән бушат! Хак нәрсә өчен һәрнәрсәдән арынып, чишен һәм Аллаһның мәгърифәтендә[125] һәм күзәтүендә эреп югалу ягын кара!..»

Кеше аңы бик чикле. Мондый чикле аң-зиһен белән чиге-ахыры булмаган илаһи бөеклекне һәм илаһи серләрне тиешенчә аңлау-төшенү мөмкин түгел. Шуңа күрә акылның төп вазифасы буйсынудан гыйбарәт.

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ акылның чиклелеген мондый мисал белән ачыклый: «Бер авыру кеше бары табибка кадәр генә бара алыр. Табибның ишеге төбендә акылның вазифасы тәгәлләнә һәм моннан соң аңа табиб киңәшләренә буйсыну йөкләнә. Шул рәвешле, мәгърифәтуллаһка лаек була алу да буйсынуның куәтенә, зурлыгына нисбәтле».

124. Ишари тәфсир – аятьләрнең тышкы мәгънәләренең аръягындагы эчке, нәфис мәгънәләрен ачу дигән сүз. Ишари тәфсирдә өч сыйфатның үтәлүе шарт: а) Тышкы мәгънәне саклау; б) Ишарә ясалган мәгънәгә дәлил булып торган төшенчәләрнең (символлар) булуы; в) бирелгән аңлатманың Коръән һәм сөннәт кысаларында булуы.

125. Җәнабел-Хакны күңел белән сөеп танып-белү.

Башкача әйткәндә, «ике нагълинеңне сал», әмере мондый мәгънә белдерә:

«Син табигатеңнән һәм нәфестән йөз чөер! Нәфесеңне һәм аңа бәйле нәрсәләрне уйлаудан тукта, кил!»

«Дәлил турында фикерләүдән баш тарт! Чөнки күз белән күргәннән соң, аларның файдасы юк!»

Шул сәбәпле шәех Шибли хәзрәтләре, Аллаһ белән кавышканнан соң, китапларның сүз-мәгънәләреннән котылып, мәгърифәтуллаһ һәм күзәтеп белү дәрьясының киңлекләрендә никадәр серле мәгънәләргә ирешүнең сөенечен кичергән.

Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Мусага изге Тува үзәнлегендә «Нагълиннәреңне сал!» дип боера, чөнки ул тирә – Хак Тәгалә җәймәсе, Аның хозурындагы урын булып тора һәм бу җирне аяк киеме белән таптап йөрү килешми. Шулай ук анда яланаяк йөрү тәкъвалык һәм әдәп җәһәтеннән дә иң күркәм рәвеш санала.

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ әсәреннән: «Иман нәрсә ул?» – дип сорадым акылымнан. Акылым йөрәгемнең колагына иелеп: «Иман әдәптән гыйбарәт!» – дип пышылдады».

Шул сәбәпле Мөхәммәд өммәтенең иң алдынгы затларыннан булган Бишр әл-Хафи һәм аңа охшаган башка кешеләр яланаяк йөргәннәр. Сәхабәләр һәм табигыйннәр дә Кәгъбә тирәли яланаяк тәваф кылган.

Башка яктан караганда, изге җирдә аяк киемнәрен салырга кушу Муса галәйһис-сәләәм аяклары аша ул тирәнең бәрәкәтеннән файда күрсен, шәрәф-хөрмәт алсын өчен кирәк була.

Ләкин шунысы бик гыйбрәтле: Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезгә Мигъраҗ кичәсендә: «И, Хәбибем! Син гареш җәймәсе өстендә аяк киемең белән йөре, гареш Синең аяк киемеңнең тузаны белән шәрәфләнсен һәм гареш нуры Синең белән кавышу нигъмәтенә лаек булсын!» – дип әйтелгәнлеге риваять кылына (Исмәгыйль Хаккы Бурсәви, «Рухул-Бәян», V, 370).

**Ике бөек могҗиза белән бирелгән пәйгамбәрлек**

«Аяк киемеңне сал!» дигән мөрәҗәгатьтән соң Муса галәйһис-сәләәмгә таягын җиргә ташларга кушыла. Таяк зур елан рәвешенә керә. Хәзрәти Муса куркуга кала. Аңа куркырга кирәкмәгәнлеге, чөнки иминлектә булганлыгы, куркыныч янамаганлыгы белдерелә.

Аяти кәримәдә болай диелә:

وَأَنْ أَلْقِ عَصَاكَ فَلَمَّا رَآهَا تَهْتَزُّ كَأَنَّهَا جَانٌّ وَلَّى مُدْبِرًا
وَلَمْ يُعَقِّبْ يَا مُوسَى أَقْبِلْ وَلَا تَخَفْ إِنَّكَ مِنَ الْآمِنِينَ

**«(Мусага) “Һәм таягыңны ташла!” (диелде) Ул (Муса) аны гүя елан кебек боргаланганын күргәч, артына борылып качты һәм кире кайтмады. (Шуннан соң:) “И, Муса! Якын кил һәм курыкма! Һичшиксез, син иминлек эчендә булган кешеләрдәнсең” (дип белдерелде)»** («әл-Касас», 31).

Муса галәйһис-сәләәмнең таягы әүвәлдә дә хикмәтле була, соңыннан исә бер кодрәткә әйләнә. Муса галәйһис-сәләәм, үзе белән азык йөртә алмаганда, аның азыгын ташып йөри торган кодрәтле нәрсәгә! Өстәвенә, Муса галәйһис-сәләәм, җәяү барудан хәлсезләнеп, гаҗиз калган чакта, таягына атлана торган була. Ул утырып торганда яки йоклаганда, таяк аңа янаган зыян-зәүрәттән һәм яманлыклардан саклый. Аңа һәртөрле җиләк-җимешне хасил итеп бирә. Эсседә утырган чакта, өстенә күләгә ясый. Газиз вә Җәлил булган Аллаһ Муса галәйһис-сәләәмгә Үз кодрәтен әнә шул таякта күрсәтә. Муса галәйһис-сәләәм исә таяк ярдәмендә Аллаһның кодрәте белән дуслаша һәм һәрчак Аны искә ала (Габдулкадыйр Гэйлани, «әл-Фәтхур-Раббани», 192 б.).

Аллаһ Тәгалә Муса галәйһис-сәләәмне пәйгамбәр итеп билгеләгәннән соң, аның белән сөйләшеп, кайбер киңәш-тәкъдимнәрен биргәндә, пәйгамбәренә болай дип дәшә:

وَمَا تِلْكَ بِيَمِينِكَ يَا مُوسَى

**«И, Муса! Уң кулыңда нәрсә ул?»** («Та-һә», 17).

Муса галәйһис-сәләәм:

قَالَ هِيَ عَصَايَ أَتَوَكَّأُ عَلَيْهَا وَأَهُشُّ بِهَا عَلَى غَنَمِي وَلِيَ فِيهَا مَآرِبُ أُخْرَى

**«Әйтте: “Бу – минем таягым. Аңа таянамын, аның белән сарыкларыма яфрак коеп төшерәмен. Аңарда минем өчен башка ихтыяҗлар да бар”»** («Та-һә», 18).

Шуннан соң Аллаһ Җәллә Җәләлүһү:

قَالَ أَلْقِهَا يَا مُوسَى

**«Әйтте: “И, Муса! Аны ыргыт!”»** («Та-һә», 19).

Хәзрәти Муса кушылганны һич кичекмәстән үти:

فَأَلْقِيهَا فَإِذَا هِيَ حَيَّةٌ تَسْعَى

**«Ул аны (шундук) ыргытты. (Ни күрсен) шунда ук ул шуышкан бер елан (түгелме)?»** («Та-һә», 20).

Моны күргәч, Муса галәйһис-сәләәм кача башлый. Ләкин Аллаһ Тәгалә:

قَالَ خُذْهَا وَلَا تَخَفْ سَنُعِيدُهَا سِيرَتَهَا الْأُولَى

**«Әйтте: “Ал аны! Курыкма! Һичшиксез, Без аны әүвәлге шәкеленә кайтарачакбыз”»** («Та-һә», 21).

Габдулкадыйр Гәйлани куддисә сирруһ бу аятьләрне түбәндәгечә аңлата:

«Аятьләрдә бәян ителгән вакыйгаларның максаты Муса галәйһис-сәләәмнең Аллаһның кодрәте турында хәбәрдар кылып, ихлас ышандырудан гыйбарәт иде. Шул дәрәҗәдә ки, Фиргавен хакимияте моннан соң аның күзенә һич тә бөек һәм кодрәтле күренерлек булмасын!

Муса галәйһис-сәләәмгә Фиргавен һәм аның кавеме белән сугышырга өйрәтү тагын бер илаһи максат булып тора. Шул рәвешле Аллаһ аны Фиргавен һәм аның халкы белән сугышка әзерләде һәм Муса галәйһис-сәләәмне искиткеч нәрсәләргә өйрәтте. Чөнки Муса галәйһис-сәләәм әүвәлрәк куркаграк, кыенсынучан була. Аннары Аллаһ аның күңелен киңәйтә. Аңа хикмәт, пәйгамбәрлек һәм гыйлем бирде».

Кайбер мөфәссирләр Муса галәйһис-сәләәмнең таягын җиргә ташлау белән бәйле аятьнең аңлатмасында бу вакыйгаларның Хәзрәти Мусаның эчке дөньясына карата тәрбия, дәрес бирү сыйфатына ия булганлыгын да искә ала. «Уң кулыңда нәрсә ул?» соравына җавабында Муса галәйһис-сәләәм фани дөньяга хас билгеләрне, нәрсәләрне искә алгач, Аллаһ Җәллә Җәләлүһү аларны ташларга куша. Нәфес һәм аңа бәйле нәрсәләр зур елан рәвешенә керә. Шул рәвешле Муса галәйһис-сәләәмгә нәфеснең чын асылы күрсәтелә. Ул исә куркуга төшә, өркеп китеп, качарга маташа. Бәян ителгән бу хәлләр белән аңа, әйтерсең, болай диелә: «И, Муса! Менә бу елан – Аллаһтан башка нәрсәләргә бәйләнеш булдыру сыйфатының нәкъ үзе. Әлеге нәфес сыйфатын билгеле бер рәвешкә кертеп, иясенә күрсәткәч, ул куркып качар».

Аяти кәримәдәге «Аны (таягыңны) ыргыт!» боерыгының да башка бер ишари мәгънәсен дә күрсәтәләр: «Син инде хәзер тәүхид сыйфатына ия. Синең нинди дер бер таякка таянып аңа ышаныч белдерүең, аңарда таяныч эзләп, ярдәм сорый торган нинди дер фани нәрсәнең булуы ничек дөрес була алсын? Ничек инде син, ул таяк белән болай итәм, анан файдаланам, ул таякта минем өчен башка файдалар да бар, дип әйтәсең? Тәүхид юлында беренче адым сәбәпләрне кире кагудан гыйбарәт. Ягъни һичшиксез буйсыну, үзеңне Аллаһка багышлау турында сүз бара. Һәртөрле теләк-үтенечтән ваз кич!»

Хәзрәти Ибраһим галәйһис-сәләәм бөтен фани нәрсәләрнең, хәтта фәрештәләрнең дә ярдәменнән баш тартып, үзенең дөньялык белән бәйләнешләреннән арына. Шул рәвешле бердәнбер Хак Тәгаләгә генә буйсыну, Аңа гына үзеңне багышлау диңгезенә чума һәм көйдергеч ут аның өчен җиләс һәм куркынычсыз нәрсәгә әйләнә.

«Хак Тәгаләнең тавышын ишеткән һәм Аның йөз нурын күргән кеше Аллаһтан башка таянган һәрнәрсәсен ташлар. Аллаһның фазыйләтеннән һәм бөеклегеннән башка бернәрсәгә дә таянмас. Нәфес теләкләреннән арыныр».

«Өммәтемнең галимнәре Бәни Исраил пәйгамбәрләре кебек!» (Аҗлуни, «Кәшфүл-Хафа», II, 64/1744).

Бу хәдис-шәрифтәге «Бәни Исраил пәйгамбәрләре кебек» гыйбарәсе Мөхәммәд өммәте галимнәрен олылау һәм хөрмәтләү өчен әйтелә.

Әүлиялардан шәех Әбү әл-Хәсән Шазәли хәзрәтләре бу мәсьәләгә мөнәсәбәтле хакыйкый төшен сөйләгән:

«Бер тәхеткә Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм утырган, башка бөтен пәйгамбәрләр исә Аның тирә-ягына тезелгәннәр иде. Алар тирәли изге галимнәр бар иде. Мин дә баскан килеш аларга карап торам һәм сүзләрен тыңлый башладым. Бервакыт Хәзрәти Муса, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә мөрәҗәгать итеп, шундый сорау бирде: “И, Аллаһның Рәсүле! Өммәтемнең галимнәре Бәни Исраил пәйгамбәрләре кебек, дип әйткән идең. Хәзер миңа алардан берәрсен күрсәтмисеңме?” Шуннан соң Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: “Менә бу!” – дип, Имам Газалине күрсәтте.

Хәзрәти Муса Газалигә дә бер сорау бирде. Газали бу сорауга ун җавап әйтте. Хәзрәти Муса җавапның сорауга туры килмәгәнен, сорауның бер генә булып, җавапның ун данә икәнлегенә ишарәләп, ризасызлык белдерде. Шулчак Имам Газали болай диде: «Бу ризасызлык сезнең өчен дә әйтелә ала. Чөнки Аллаһ Тәгалә сездән: “И, Муса! Уң кулыңда нәрсә ул?” – дип сораган иде. Бу сорауның җавабы “бу – минем таягым!” рәвешендә генә әйтелергә тиеш булса да, сез тагын бик күп сыйфатларын санадыгыз!..»

Шазәли куддисә сирруһ сүзен болай дип дәвам итә:

«Мин ул вакытта Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дәрәҗәсенең бөеклеге, Аның – тәхеттә, башка пәйгамбәрләрнең исә җирдә утырулары турында уйга чумганда, кемдер аягы белән шундый итеп төртте ки, мизгел эчендә уянып киттем. “Әл-Әкъса” мәчетенең шәмнәрен яндырып йөрүче хезмәткәр булган икән. Ул миңа: “Гаҗәпләнмә! Һәрнәрсә Хәзрәти Мөхәммәд Мостафаның нурыннан яратылды”, – диде. Моны ишетүгә, аңымны югалтып егылдым. Җәмәгать намазы беткәч кенә һушыма килә алдым һәм шундук теге хезмәткәрне эзләдем. Тик аны бүгенгәчә таба алганым юк» (Рагыйб әл-Исфәхани, «әл-Мухадарат»).

Икенче бер могҗиза буларак, Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәмгә кулын куенына тыгарга кушыла. Муса галәйһис-сәләәм бу илаһи әмерне үтәгәч, кулы бөтен чир-авырулардан сау-сәламәт һәм якты кояштай ап-ак рәвешкә керә. Әйтерсең, кулы прожекторга әйләнә. Муса галәйһис-сәләәм бик аптыраашта

кала. Шуннан соң аңа: «Кулыңның мондый яктылык чәчеп торуы сине һәм башкаларны куркытса, кулыңны кабат куеныңа тык! Шулай итеп ул янә әүвәлге рәвешенә кайтыр!» – дип хәбәр ителә.

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәмгә бирелгән «йәди бәйза» (ап-ак, якты кул) могҗизасы аяти кәримәләрдә түбәндәгечә сурәтләнә:

وَاضْمُمْ يَدَكَ إِلَى جَنَاحِكَ تَخْرُجْ بَيْضَاءَ مِنْ غَيْرِ سُوءٍ آيَةً أُخْرَى. لِنُرِيَكَ مِنْ آيَاتِنَا الْكُبْرَى

**«Һәм кулыңны янтыгыңа тык, бернинди кимчелек булмыйча, бер могҗиза буларак, ап-ак булып чыксын. Без сиңа иң зур могҗизаларыбыздан бер өлешен күрсәтер өчен (эшлибез)»** («Та-һә», 22–23).

اُسْلُكْ يَدَكَ فِي جَيْبِكَ تَخْرُجْ بَيْضَاءَ مِنْ غَيْرِ سُوءٍ وَاضْمُمْ إِلَيْكَ جَنَاحَكَ مِنَ الرَّهْبِ
فَذَانِكَ بُرْهَانَانِ مِنْ رَبِّكَ إِلَى فِرْعَوْنَ وَمَلَائِهِ إِنَّهُمْ كَانُوا قَوْمًا فَاسِقِينَ

**«(Мусага) “Кулыңны яка астына тык, бернинди кимчелек булмыйча, бер могҗиза буларак, ап-ак булып чыксын. Янә куркудан канатларыңны (ачылган кулларыңны) үзеңә кыс. Болар (таяк һәм ак кул) – фиргавен һәм аның олуг кешеләренә Раббыңнан ике ачык дәлил. Һичшиксез, алар фасикълар кавеме булдылар!” (дип вәхи иңдерелде)»** («әл-Касас», 32).

Шул рәвешле Аллаһ Тәгалә Муса галәйһис-сәләәмгә ике бөек могҗиза белән бергә пәйгамбәрлек вазифасын йөкли, дингә өндәргә куша. Моның өчен иң әүвәл Фиргавен янына барырга боера:

اِذْهَبْ إِلَى فِرْعَوْنَ إِنَّهُ طَغَى

**«Фиргавенгә бар. Һичшиксез, ул (гаять) азынды»** («Та-һә», 24).

Шуннан соң Муса галәйһис-сәләәм:

قَالَ رَبِّ إِنِّي قَتَلْتُ مِنْهُمْ نَفْسًا فَأَخَافُ أَنْ يَقْتُلُونِ

**«Әйтте: “И, Раббым! Мин алардан бер кешене үтергән идем,[126] шул сәбәпле аларның мине үтерүләреннән куркамын”»** («әл-Касас», 33).

Аннары бертуганы Һарунны да үзенә ярдәмче итеп бирелүен сорый:

وَأَخِي هَارُونُ هُوَ أَفْصَحُ مِنِّي لِسَانًا فَأَرْسِلْهُ مَعِيَ رِدْءًا يُصَدِّقُنِي إِنِّي أَخَافُ أَنْ يُكَذِّبُونِ

**«Абыем Һарун тел ягыннан миннән өстенрәк, янымда мине раслаган бер ярдәмче итеп аны да җибәр. Мин аларның мине ялганчы дип санауларыннан (гаепләүләреннән) куркамын!»** («әл-Касас», 34).

126. Югарыда белдерелгәнчә, Муса галәйһис-сәләәм кыптыйга үтерү нияте белән түгел, ә туктату, аеру максатында суга. Ләкин илаһи моратның чынга ашуы буларак, кыптый кеше үлеп китә.

قَالَ سَنَشُدُّ عَضُدَكَ بِأَخِيكَ وَنَجْعَلُ لَكُمَا سُلْطَانًا فَلَا
يَصِلُونَ إِلَيْكُمَا بِآيَاتِنَا أَنْتُمَا وَمَنِ اتَّبَعَكُمَا الْغَالِبُونَ

**«(Аллаһ Тәгалә) әйтте: “Без сине кардәшең белән куәтләячәкбез һәм икегезгә хакимият (куәт) бирәчәкбез, алар сезгә зыян сала алмаячаклар. Аятьләребез ярдәме белән сез икегез дә, сезгә иярүчеләр дә җиңәчәксез!”»** («әл-Касас», 35).

Риваятькә күрә, Җәнабел-Хак:

**«Фиргавенгә бар. Һичшиксез, ул (гаять) азынды»**, – дип боерган чакта («Та-һә», 24), Муса галәйһис-сәләәм гаиләсен һәм мал-туарын әманәт итеп калдырырга һичкем күренмәгәнлектән: «Йә, Раббы! Гаиләмә һәм малларыма ни булыр?» – дип борчыла. Моңа җавабында Җәнабел-Хак, «саклаучыларның иң хәерлесе» икәнлеген искә төшереп, болай ди: «Әй, Муса! Мине белгәннән соң, таныганнан соң, сиңа тагын ни кирәк? Син Минем әмеремне үтәргә ашык! Миңа тапшыр һәм буйсын! Теләсәм, бүрене – сарыкларга көтүче, фәрештәләремне исә гаиләңә сакчы итеп куярмын. Әй, Муса! Нәрсә уйлавың бу? Әниең диңгезгә ташлаган вакытта, сине кем коткарды? Соңыннан сине әниең белән кем кабат кавыштырды? Син берәүне казада үтергән идең һәм Фиргавен сине эзли башлады. Шулвакытта сине аннан кем саклады?..»

Муса галәйһис-сәләәм бу сүзләрне тыңлый-тыңлый, һәр җөмлә ахырында: «Син, Син, Син, йә Раббы!..» – дип кабатлый (Әхмәд әр-Руфаи, «Халәтү әһлил-Хакыйкати Мәаллаһ», 337 б.).

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм Мисырга килә. Фиргавеннең бик зур гаскәре турында уйлап йөри. Абыйсына һәм аңа Аллаһ Тәгалә: «Сез икегез Минем гаскәрләремнән ике зур гаскәр булып торасыз! Димәк, зәгыйфь һәм куәтсез була алмыйсыз!» – дип белдерә. Муса галәйһис-сәләәм, үзенә йөкләнгән олуг вазифаның кыенлыгы каршында борчылып, Җәнабел-Хактан ярдәм сорап ялвара:

قَالَ رَبِّ اشْرَحْ لِي صَدْرِي. وَيَسِّرْ لِي أَمْرِي. وَاحْلُلْ عُقْدَةً مِنْ لِسَانِي. يَفْقَهُوا قَوْلِي.
وَاجْعَلْ لِي وَزِيرًا مِنْ أَهْلِي. هَارُونَ أَخِي. اُشْدُدْ بِهِ أَزْرِي. وَأَشْرِكْهُ فِي أَمْرِي. كَيْ
نُسَبِّحَكَ كَثِيرًا. وَنَذْكُرَكَ كَثِيرًا. إِنَّكَ كُنْتَ بِنَا بَصِيرًا. قَالَ قَدْ أُوتِيتَ سُؤْلَكَ يَا مُوسَى

**«Әйтте: “И, Раббым! Минем күкрәгемне киң кыл! Эшемне миңа җиңел кыл. Телемдәге (бу) төенне чиш. Сүземне яхшы аңлый алсыннар. Гаиләмнән миңа бер вәзир (ярдәмче) билгелә. Кардәшем Һарунны. Аның белән көчемне ныгыт. Эшемдә дә аны уртак ит. Без Сине күп итеп тәсбих итәр өчен. Һәм Сине күп итеп зикер итәр өчен. Һичшиксез, Син бит безне**

**күрәсең”». (Мусаның бу үтенечен кабул итеп), Ул (Аллаһ) әйтте: «И, Муса! Сораганнарың сиңа бирелде инде»** («Та-һә», 25–36).

Соңрак Хак Тәгалә аңа ирештергән нигъмәтләре һәм аның Аллаһ тарафыннан саклануы турында болай дип хәтергә төшерә:

وَلَقَدْ مَنَنَّا عَلَيْكَ مَرَّةً أُخْرَى. إِذْ أَوْحَيْنَا إِلَى أُمِّكَ مَا يُوحَى.
أَنِ اقْذِفِيهِ فِي التَّابُوتِ فَاقْذِفِيهِ فِي الْيَمِّ فَلْيُلْقِهِ الْيَمُّ بِالسَّاحِلِ يَأْخُذْهُ عَدُوٌّ لِي
وَعَدُوٌّ لَهُ وَأَلْقَيْتُ عَلَيْكَ مَحَبَّةً مِنِّي وَلِتُصْنَعَ عَلَى عَيْنِي

**«Һичшиксез, Без сиңа башка вакытта да игелек кылган идек. Менә Без вәхи ителгән нәрсәне әниеңә вәхи иттек: “Аны табутка сал, шуннан аны елгага (Нилгә) җибәр, диңгез аны ярга чыгарсын. Минем дошманым һәм аның дошманы аны алсын”. (И, Муса!) Мин сиңа Үземнән бер сөю бирдем. Син – (сине сөйсеннәр һәм) Минем күзәтүем астында үстерелүең өчен»** («Та-һә», 37–39).

إِذْ تَمْشِي أُخْتُكَ فَتَقُولُ هَلْ أَدُلُّكُمْ عَلَى مَنْ يَكْفُلُهُ فَرَجَعْنَاكَ إِلَى
أُمِّكَ كَيْ تَقَرَّ عَيْنُهَا وَلَا تَحْزَنَ وَقَتَلْتَ نَفْسًا فَنَجَّيْنَاكَ مِنَ الْغَمِّ وَفَتَنَّاكَ
فُتُونًا فَلَبِثْتَ سِنِينَ فِي أَهْلِ مَدْيَنَ ثُمَّ جِئْتَ عَلَى قَدَرٍ يَا مُوسَى

**«Менә апаң барды да: “Аны карый алырлык кешене күрсәтимме сезгә? ” – диде. Шулай итеп, күңеле тыныч булсын һәм сагышланмасын өчен, Без сине әниеңә кире кайтардык. Син бер кешене үтердең, Без исә сине ул хәсрәттән коткардык. Шушылай Без сине төрле-төрле фетнәләр белән сынадык. И, Муса! Син еллар буена Мәдйән халкы арасында булдың, соңыннан тәгаенләнгән вакытта (бу урынга) килдең!»** («Та-һә», 40).

وَاصْطَنَعْتُكَ لِنَفْسِي. اِذْهَبْ أَنْتَ وَأَخُوكَ بِآيَاتِي وَلَا تَنِيَا فِي ذِكْرِي. اِذْهَبَا إِلَى فِرْعَوْنَ إِنَّهُ طَغَى

**«Мин сине Үзем өчен (илче итеп) сайладым. Син һәм кардәшең аятьләрем белән барыгыз. Әмма зикерем мәсьәләсендә йомшаклык күрсәтмәгез. Фиргавенгә барыгыз! Һичшиксез, ул чиктән ашты»** («Та-һә», 41–43).

Муса белән Һарун галәйһимәс-сәләмгә, үзләре пәйгамбәр була торып та, Җәнабел-Хак зикер әйтергә боера, моннан исә бу илаһи әмернең безнең өчен никадәр мөһим икәнлеге ачык аңлашыла. Йөрәкне тәрбияләү һәр мөэмин өчен зарури. Иман җәүһәренең мәркәзен йөрәк тәшкил иткән кебек, зикер җәүһәренең үзәге дә – йөрәк. Зикер йөрәккә кереп урнашкан вакытта чын тынычлыкка, иминлеккә ирешеп була.

Аяти кәримәдә:

اَلَّذِينَ آمَنُوا وَتَطْمَئِنُّ قُلُوبُهُم بِذِكْرِ اللَّهِ أَلَا بِذِكْرِ اللَّهِ تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ

**«Алар – иман китергән һәм күңелләре Аллаһны зикер итү белән тынычланган кешеләр. Күңелләр Аллаһны зикер итү белән тынычланмыймы?!» – дип ассызыклана** («әр-Рәгъд», 28).

«Ниса» сүрәсенең 28 нче аяти кәримәсендә әйтелгәнчә, кеше зәгыйфь итеп яралтылган. Дини хис-тойгылар йөрәктә ныгыган саен, нәфес теләкләре аннан ерагая барыр. Дин кешене тышкы килеш-кыяфәтендә генә күрергә теләми. Кеше – югары дәрәҗәле мәхлук ул. Аның өлгерүе, камилләшүе таләп ителә. Күңел тормышына әһәмият бирмичә торып, күңелгә хуш килерлек, сизгер һәм нәфис рухлы мөселман булу мөмкин түгел. Җәнабел-Хак гыйбадәтләрнең бары кушылган тышкы рәвештә генә башкарылуына риза булмас. Мәсәлән, намазның күңел уяулыгы белән укылуын тели.

قَدْ أَفْلَحَ الْمُؤْمِنُونَ. الَّذِينَ هُمْ فِي صَلَاتِهِمْ خَاشِعُونَ

**«Иман китерүчеләр хәзердән уңышка иреште. Кемнәр намазларында түбәнчелеклеләр (хошуглы, өлгергән йөрәкле)!»** («әл-Мүэминүн», 1–2).

Җәнабел-Хак намазның хошугсыз (өлгергән йөрәктән мәхрүм хәлдә) кылынуын теләми. Аяти кәримәдә:

فَوَيْلٌ لِلْمُصَلِّينَ. اَلَّذِينَ هُمْ عَنْ صَلَاتِهِمْ سَاهُونَ

**«Намаз укыганнарга ни үкенеч! Намазларында гафилләргә!»** – диелә («әл-Мәгун», 4–5).

Җәнабел-Хак җанын зикер белән камилләштермәгән затларга карата мондый кисәтү ясый:

فَوَيْلٌ لِلْقَاسِيَةِ قُلُوبُهُمْ مِنْ ذِكْرِ اللَّهِ أُولَئِكَ فِي ضَلَالٍ مُبِينٍ

**«...Аллаһның зикеренә (карата йөрәкләре) каты булганнарга ни үкенеч! Алар ап-ачык бер адашу эчендә»** («әз-Зүмәр», 22).

ЧөнкиЛәтыйф (йомшак, нәзек) булган Җәнабел-Хакка бихисап гөнаһлар һәм дөньяви кызыксынуларның авырлыгы баскан йөрәк белән якынаеп булмый. Йөрәкне нәфес афәтләреннән саклар өчен, зикер зарури таләп булып тора.

Хәзрәти Муса белән Хәзрәти Һарун галәйһимәс-сәләм Нил елгасы ярында очрашып кочаклаша. Хәзрәти Муса абыйсы Һарунга: «Әйдә, Фиргавен янына барыйк! Чөнки Аллаһ Җәллә Җәләлүһү икебезгә дә шул эшне йөкләде», – ди.

Аннары икәүләп:

قَالَا رَبَّنَا إِنَّنَا نَخَافُ أَنْ يَفْرُطَ عَلَيْنَا أَوْ أَنْ يَطْغَى. قَالَ لَا تَخَافَا إِنَّنِي مَعَكُمَا أَسْمَعُ وَأَرَى

**«Әйттеләр: “И, Раббыбыз! Без аның үзебезгә каршы чамадан узуыннан яки азуыннан куркабыз”». (Аллаһ Тәгалә) әйтте: «Икегез дә курыкмагыз! Һичшиксез, Мин – сезнең белән бергә. Ишетәм һәм күрәм»** («Та-һә», 45–46).

فَأْتِيَا فِرْعَوْنَ فَقُولَا إِنَّا رَسُولُ رَبِّ الْعَالَمِينَ. أَنْ أَرْسِلْ مَعَنَا بَنِي إِسْرَائِيلَ

**«Икегез дә Фиргавенгә барыгыз да әйтегез: “Без – галәмнәр Раббысының илчеләребез. Исраил улларын безнең белән бергә җибәр, дип”»** («әш-Шугара», 16–17).

Ләкин Аллаһ Тәгалә дингә өндәгәндә кулланылырга тиешле өслүпне дә белдереп куя:

فَقُولَا لَهُ قَوْلًا لَيِّنًا لَعَلَّهُ يَتَذَكَّرُ أَوْ يَخْشَى

**«Аңа йомшак бер сүз әйтегез. Бәлки ул үгетләнер яки куркыр!»** («Таһә», 44).

Хак Тәгалә дусларыннан Язид әр-Раккаши бу аятьне укыгач: «Хәтта үзеңә карата дошманлык кылучыга да мәрхәмәтле мөгамәлә күрсәтергә кушкан Аллаһым! Синең дустың булып, бәндәләрне Сиңа чакыручыга нинди мөгамәләдә булырсың икән!» – дип әйткән.

Фиргавеннең тәүхид гакыйдәсенә иярмәячәген илаһи гыйлеме белән белгән килеш тә, Җәнабел-Хак Муса галәйһис-сәләәмгә Фиргавен белән йомшак телдә сөйләшергә куша. Хәзрәти Муса шәхесе аша әлеге тәгълимат «әмри бил-мәгъруф вә нәһйи ганил-мүнкәр» белән шөгыльләнгән бөтен мөэминнәргә белдерелә.

Бу мәсьәлә белән бәйле рәвештә, Җәнабел-Хак Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезнең йомшак, шәфкатьле, мәрхәмәтле һәм түземле тәблигъ методын аяти кәримәдә мактап телгә ала:

فَبِمَا رَحْمَةٍ مِنَ اللَّهِ لِنْتَ لَهُمْ وَلَوْ كُنْتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ لَانْفَضُّوا مِنْ حَوْلِكَ فَاعْفُ عَنْهُمْ
وَاسْتَغْفِرْ لَهُمْ وَشَاوِرْهُمْ فِي الْأَمْرِ فَإِذَا عَزَمْتَ فَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ الْمُتَوَكِّلِينَ

**«(Ул вакытта) Аллаһтан шәфкать белән син аларга йомшак булдың. Әгәр дә дорфа, каты күңелле булсаң, алар синең яннан таралып киткән булырлар иде. Аларны кичер, алар өчен кичерү сора, (кылачак) эшләрдә алар белән киңәш. Әмма карарга килсәң, шунда ук Аллаһка тапшыр. Һичшиксез, Аллаһ тәвәккәл итүчеләрне сөя»** («Әли Гыймран», 159).

**Ахмак Фиргавен**

Хәзрәти Муса һәм Хәзрәти Һарун галәйһимәс-сәләм, илаһи әмердә кушылганча, икәүләп Фиргавен янына юл тоталар.

Фиргавен Муса галәйһис-сәләәмне: «Кем син?» – дип каршылый. Тегесе исә: «Мин галәмнәрнең Раббысы җибәргән Пәйгамбәр!» – дип җавап бирә. Фиргавен башта бик гаҗәпләнә. Аннары исә элек Хәзрәти Мусага кылган игелекләрен искә төшерә-төшерә, ачуланып, аны гаепли башлый: «Син минем сараемда үстең. Икмәк пешерүчемне үтердең. Ничек син хәзер шундый эшкә җөрьәт итәсең?!»

Бу әңгәмә, Корьәни-Кәримдә болай тасвирлана:

قَالَ أَلَمْ نُرَبِّكَ فِينَا وَلِيدًا وَلَبِثْتَ فِينَا مِنْ عُمُرِكَ سِنِينَ. وَفَعَلْتَ فَعْلَتَكَ الَّتِي فَعَلْتَ وَأَنْتَ مِنَ الْكَافِرِينَ

**«(Аңа Аллаһның кушканнары хәбәр ителгәч, ахмак Фиргавен) әйтте: “Без сине туганнан соң арабызда тәрбияләп үстермәдекме? Син гомереңнең күп елларын безнең арабызда тормадыңмы? Һәм син нигъмәтемне инкяр итүчеләрдән булып, кылган (яман) эшеңне кылдың”»** («әш-Шугара», 18–19).

Муса галәйһис-сәләәм исә:

قَالَ فَعَلْتُهَا إِذًا وَأَنَا مِنَ الضَّالِّينَ. فَفَرَرْتُ مِنْكُمْ لَمَّا خِفْتُكُمْ فَوَهَبَ لِي رَبِّي حُكْمًا وَجَعَلَنِي مِنَ الْمُرْسَلِينَ. وَتِلْكَ نِعْمَةٌ تَمُنُّهَا عَلَيَّ أَنْ عَبَّدْتَ بَنِي إِسْرَائِيلَ

**«Әйтте: “Ул вакытта мин аны кылдым, әмма белмәгәннәрдән идем (кыптыйны махсус үтермәдем). Сездән курыккач, арагыздан качтым. Шуннан соң Раббым миңа хөкем бирде һәм мине (пәйгамбәр итеп) җибәрелгәннәрдән итте. Ул син мине битәрләгән нигъмәт исә, Исраил улларын кол иткән булуың (нәтиҗәсендә түгелме)?!”»** («әш-Шугара», 20–22).

Муса галәйһис-сәләәм сүзен дәвам итә: «Менә син менә болай золым кылдың, мине гаиләмнән аердың! Ә соңыннан Раббым миңа гыйлем һәм хикмәт бирде. Мине Пәйгамбәр итте». Ләкин:

قَالَ فَمَنْ رَبُّكُمَا يَا مُوسَى

**«(Фиргавен) әйтте: “И, Муса! Сезнең икегезнең Раббысы кем соң?”»** («Та-һә», 49).

قَالَ فِرْعَوْنُ وَمَا رَبُّ الْعَالَمِينَ

**«Фиргавен әйтте: “Нәрсә ул галәмнәрнең Раббысы?”»** («әш-Шугара», 23).

قَالَ رَبُّنَا الَّذِي أَعْطَى كُلَّ شَيْءٍ خَلْقَهُ ثُمَّ هَدَى

**«Әйтте: “Безнең Раббыбыз – һәрнәрсәгә шәкелен (барлыгын һәм рәвешен) биргән, шуннан соң (туры юлга) ирештергән”»** («Та-һә», 50).

Аннары Муса галәйһис-сәләәм:

قَالَ رَبُّ السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ وَمَا بَيْنَهُمَا إِنْ كُنْتُمْ مُوقِنِينَ

**«Әйтте: “Күкләрнең, җирнең һәм алар арасындагыларның Раббысы. Әгәр шиксез ышанган кешеләр булсагыз (игътибар итәрсез)”»** («әш-Шугара», 24).

قَالَ فَمَا بَالُ الْقُرُونِ الْأُولَى. قَالَ عِلْمُهَا عِنْدَ رَبِّي فِي كِتَابٍ لَا يَضِلُّ رَبِّي وَلَا يَنْسَى. الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ الْأَرْضَ مَهْدًا وَسَلَكَ لَكُمْ فِيهَا سُبُلًا وَأَنْزَلَ مِنَ السَّمَاءِ مَاءً فَأَخْرَجْنَا بِهِ أَزْوَاجًا مِنْ نَبَاتٍ شَتَّى

**(Фиргавен) әйтте: «Ул әүвәлге нәселләрнең хәлләре нинди?» (Муса) әйтте: «Алар турында гыйлем Раббым хозурындагы китапта. Раббым ялгышмый һәм онытмый. Ул (Аллаһ) җирне сезнең өчен түшәк итте, анда сезнең өчен юллар барлыкка китерде һәм күктән су яудырды...»** («Та-һә», 51–53).

قَالَ لِمَنْ حَوْلَهُ أَلَا تَسْتَمِعُونَ. قَالَ رَبُّكُمْ وَرَبُّ آبَائِكُمُ الْأَوَّلِينَ. قَالَ إِنَّ رَسُولَكُمُ الَّذِي أُرْسِلَ إِلَيْكُمْ لَمَجْنُونٌ. قَالَ رَبُّ الْمَشْرِقِ وَالْمَغْرِبِ وَمَا بَيْنَهُمَا إِنْ كُنْتُمْ تَعْقِلُونَ

**«Ул (Фиргавен) янәшәсендәгеләргә: “Ишетмисезме әллә?” – диде. Ул (Муса, сүзен дәвам итеп): “Сезнең дә Раббыгыз, әүвәлге аталарыгызның да Раббысы!” – диде. (Үзенең тәңре булганлыгын белдергән Фиргавен бу сүзләргә кызып китә) Ул: “Һичшиксез сезгә җибәрелгән бу рәсүлегез бер тиле”, – диде. Ул (Муса): “Көнчыгышның, көнбатышның һәм икесе арасында булганнарның Раббысы. Әгәр сез (акылыгызны кулланып) аңласагыз”, – диде»** («әш-Шугара», 25–28).

Шуннан соң Фиргавен Хәзрәти Муса белән Һарун галәйһимәс-сәләмгә газап-җәфалы үлем җәзасының бер төре булган төрмә белән яный башлый:

قَالَ لَئِنِ اتَّخَذْتَ إِلَهًا غَيْرِي لَأَجْعَلَنَّكَ مِنَ الْمَسْجُونِينَ. قَالَ أَوَلَوْ جِئْتُكَ بِشَيْءٍ مُبِينٍ. قَالَ فَأْتِ بِهِ إِنْ كُنْتَ مِنَ الصَّادِقِينَ. فَأَلْقَى عَصَاهُ فَإِذَا هِيَ ثُعْبَانٌ مُبِينٌ

**«Ул (Фиргавен): “Әгәр миннән башка бер илаһ алсаң, мин сине төрмәгә ябылучылардан итәрмен”, – диде. Ул (Муса): “Мин сиңа ап-ачык нәрсә китерсәм дәме?” – диде. Ул (Фиргавен): “Әйдә, аны китер. Әгәр син тугрылардан булсаң”, – диде. Ул (Муса) таягын ташлады һәм кинәт ул ап-ачык еланга әверелде!»** («әш-Шугара», 29–32).

Үзен тәңре дип йөрткән Фиргавен, бу могҗизаларны күреп, куркуга төшә, тәмам коты очып: «Зинһар, аны тот! Бөтен Бәни Исраил кешеләрен ireккә җибәрермен!» – ди. Муса галәйһис-сәләәм таякны кулына ала. Таягы кабат әүвәлге рәвешенә кайта. Фиргавен: «Башкасы тагын бармы?» – дип сорый.

وَنَزَعَ يَدَهُ فَإِذَا هِيَ بَيْضَاءُ لِلنَّاظِرِينَ

**«(Муса галәйһис-сәләәм) Янә кулын (куенына тыгып) чыгарды, кинәт ул караучылар өчен ап-ак (күзләрне камаштыргыч нурлы) иде»** («әш-Шугара», 33).

Фиргавен янә куркуга кала. Бу могҗизалардан соң Муса галәйһис-сәләәмгә иман китерер дәрәҗәгә җитә диярлек. Фәкать вәзире Һаман моңа каршы төшеп, Фиргавенне котыртырга керешә: «Син тәңре бит! Башка берәүгә буйсыну сиңа килешми! Һәркем сине тәңре дип белә, син тәңредән кол дәрәҗәсенә төшмә. Без моңа берәр чарасын табарбыз!»

قَالَ لِلْمَلَإِ حَوْلَهُ إِنَّ هَذَا لَسَاحِرٌ عَلِيمٌ. يُرِيدُ أَنْ يُخْرِجَكُمْ مِنْ أَرْضِكُمْ بِسِحْرِهِ فَمَاذَا تَأْمُرُونَ

**«Янәшәсендә булган абруйлы затларга (Фиргавен) әйтте: “Һичшиксез, бу – бик белемле сихерче. Ул сезне туфрагыгыздан сихере белән чыгарырга тели. Нәрсә әмер итәсез?”»** («әш-Шугара», 34–35).

**Могҗиза белән сихернең ярышы**

Хәзрәти Муса күрсәткән могҗизалар Фиргавеннең горурлык хисен челпәрәмә китерә. Шуңа күрә ул, үзенең тәңре булуга дәгъвасын читкә этәреп, үз тирәсендәге алдынгы бәндәләр белән киңәшергә мәҗбүр хәлдә кала.

قَالُوا أَرْجِهْ وَأَخَاهُ وَابْعَثْ فِي الْمَدَائِنِ حَاشِرِينَ. يَأْتُوكَ بِكُلِّ سَحَّارٍ عَلِيمٍ

**«Әйттеләр: “Аны һәм кардәшен кичектер дә җыючыларны шәһәрләргә җибәр. Алар сиңа һәр белемле сихерчене алып килсеннәр!”»** («әш-Шугара», 36–37).

Ул заманда сихерчелек бик алга китә. Шунлыктан Фиргавен мондый тәкъдимне кичекмәстән кабул итә.

Аллаһ Тәгалә әйтә:

وَلَقَدْ أَرَيْنَاهُ آيَاتِنَا كُلَّهَا فَكَذَّبَ وَأَبَى. قَالَ أَجِئْتَنَا لِتُخْرِجَنَا مِنْ أَرْضِنَا بِسِحْرِكَ يَا مُوسَى. فَلَنَأْتِيَنَّكَ بِسِحْرٍ مِثْلِهِ فَاجْعَلْ بَيْنَنَا وَبَيْنَكَ مَوْعِدًا لَا نُخْلِفُهُ نَحْنُ وَلَا أَنْتَ مَكَانًا سُوًى

**«Без аңа (Фиргавенгә) могҗизаларның бөтенесен күрсәттек, ләкин ул ялган дип санады һәм баш тартты. Әйтте: "И, Муса! Син сихерең белән безне торган җиребездән чыгарыр өчен килдеңме әллә? Без сиңа, һичшиксез, моның кебек бер сихер күрсәтәчәкбез. Безнең белән синең арада бер килешү буларак тигез бер урын билгелә дә без дә, син дә аны бозмас булыйк!"»** («Та-һә», 56–58).

قَالَ مَوْعِدُكُمْ يَوْمُ الزِّينَةِ وَأَنْ يُحْشَرَ النَّاسُ ضُحًى. فَتَوَلَّى فِرْعَوْنُ فَجَمَعَ كَيْدَهُ ثُمَّ أَتَى

**«(Муса галәйһис-сәләәм) әйтте: "Сезгә вәгъдә ителгән вакыт – зиннәт (бәйрәм) көне һәм кешеләр җыелачак төштән алдагы вакыт". Фиргавен борылып китте, хәйләсен (чараларын) туплады һәм шуннан соң килде»** («Та-һә», 59–60).

فَجُمِعَ السَّحَرَةُ لِمِيقَاتِ يَوْمٍ مَعْلُومٍ. وَقِيلَ لِلنَّاسِ هَلْ أَنْتُمْ مُجْتَمِعُونَ

**«Сихерчеләр танылган бер көннең билгеләнгән вакытында бер урынга китерелде. Кешеләргә әйтелде: "Сез җыелдыгызмы? (Тизрәк туплаңыгыз)"»** («әш-Шугара», 38–39).

Ярыш көнендә бар халык җыела. Кешеләр ни булачагын тизрәк күрергә теләп, сабырсызлана.

لَعَلَّنَا نَتَّبِعُ السَّحَرَةَ إِنْ كَانُوا هُمُ الْغَالِبِينَ. فَلَمَّا جَاءَ السَّحَرَةُ قَالُوا لِفِرْعَوْنَ أَئِنَّ لَنَا لَأَجْرًا إِنْ كُنَّا نَحْنُ الْغَالِبِينَ. قَالَ نَعَمْ وَإِنَّكُمْ إِذًا لَمِنَ الْمُقَرَّبِينَ

**«(Фиргавен кешеләре әйтә:) "Бәлки, без сихерчеләргә иярербез. Әгәр алар җиңсәләр". Сихерчеләр Фиргавенгә килгәч: "Әгәр дә без җиңүчеләр булсак, безгә бер түләү булырмы?" – диделәр. Ул: "Әйе! Ул тәкъдирдә сез якын ителгәннәрдән булачаксыз (һич шикләнмәгез)", – диде»** («әш-Шугара», 40–42).

Фиргавен: «Яхшы, ә сез Мусаны җиңә аласызмы?» – дип сорагач, баш сихерче аны тынычландырырга ашыга: «Без сихер эшенең иң югары дәрәҗәсенә ирештек! Бу эшне җир йөзендә бездән дә яхшырак белүче юктыр!

Ягъни без иң югарының да өске ягында! Күктән җимергеч көч килеп төшмәсә, аны һичшиксез җиңәрбез. Әлбәттә, без көчлерәк һәм куәтлерәк!»

Муса галәйһис-сәләәм исә сихерчеләрне кисәтеп куя:

قَالَ لَهُمْ مُوسَى وَيْلَكُمْ لَا تَفْتَرُوا عَلَى اللّٰهِ كَذِبًا فَيُسْحِتَكُمْ بِعَذَابٍ وَقَدْ خَابَ مَنِ افْتَرَى

**«Муса аларга: “Ни үкенеч сезгә! Аллаһка карата ялган кормагыз, шуннан соң Ул сезне газаплар белән тамырыгызны корытып һәлак итәр. Яла яккан кеше уңышсызлыкка ирешәчәк”, – диде»** («Та-һә», 61).

Бу кисәтү сихерчеләрне уйланырга мәҗбүр итә:

فَتَنَازَعُوا أَمْرَهُم بَيْنَهُمْ وَأَسَرُّوا النَّجْوَى. قَالُوا إِنْ هَذَانِ لَسَاحِرَانِ يُرِيدَانِ
أَنْ يُخْرِجَاكُمْ مِنْ أَرْضِكُم بِسِحْرِهِمَا وَيَذْهَبَا بِطَرِيقَتِكُمُ الْمُثْلَى

**«Алар эшләре турында үзара тартыштылар һәм пышылдашуларын яшерен тоттылар. Әйттеләр: “Һичшиксез, бу икәү (Муса белән Һарун) – сихерчеләр. Алар сихерләре белән сезне торган җирегездән чыгарырга һәм сезнең өстен юлыгызны юк итәргә телиләр!”»** («Та-һә», 62–63).

Шуннан соң Муса галәйһис-сәләәм:

فَأَجْمِعُوا كَيْدَكُمْ ثُمَّ ائْتُوا صَفًّا وَقَدْ أَفْلَحَ الْيَوْمَ مَنِ اسْتَعْلَى

**«Хәйләгезне берләштерегез дә, бер саф булып килегез. Бүген өстен чыккан кеше морадка ирешер»**, – дип әйтә («Та-һә», 64).

Һичнигә карамастан сихерчеләр, Хәзрәти Мусага хөрмәт һәм илтифат күрсәтеп, ярышны башларга тәкъдим итәләр:

قَالُوا يَا مُوسَى إِمَّا أَنْ تُلْقِيَ وَإِمَّا أَنْ نَكُونَ أَوَّلَ مَنْ أَلْقَى. قَالَ بَلْ أَلْقُوا

**«Әйттеләр: “И, Муса! Синме беренче булып ыргытасың, безме беренче булып ыргытыйк?” Ул (Муса): “Юк, сез (башта) ыргытыгыз”, – диде»** («Та-һә», 65–66).

قَالَ لَهُمْ مُوسَى أَلْقُوا مَا أَنْتُمْ مُلْقُونَ. فَأَلْقَوْا حِبَالَهُمْ
وَعِصِيَّهُمْ وَقَالُوا بِعِزَّةِ فِرْعَوْنَ إِنَّا لَنَحْنُ الْغَالِبُونَ

**«Муса аларга: “Сез ыргытасы нәрсәләрегезне ыргытыгыз”, – диде. Алар бауларын һәм таякларын ыргыттылар да: “Фиргавеннең көче хакына, һичшиксез, без җиңүчеләрбез”, – диделәр»** («әш-Шугара», 43–44).

فَإِذَا حِبَالُهُمْ وَعِصِيُّهُمْ يُخَيَّلُ إِلَيْهِ مِنْ سِحْرِهِمْ أَنَّهَا تَسْعَى. فَأَوْجَسَ فِي نَفْسِهِ خِيفَةً مُوسَى. قُلْنَا لَا تَخَفْ إِنَّكَ أَنْتَ الْأَعْلَى. وَأَلْقِ مَا فِي يَمِينِكَ تَلْقَفْ مَا صَنَعُوا إِنَّمَا صَنَعُوا كَيْدُ سَاحِرٍ وَلَا يُفْلِحُ السَّاحِرُ حَيْثُ أَتَى

**«…(Муса бер караганда), сихерләре сәбәпле җепләре вә таяклары аңа хәрәкәтләнгән кебек күренде. Муса күңелендә бер курку сизде. Без (аңа) әйттек: “Курыкма! Һичшиксез, син өстен чыгачаксың. Уң кулыңдагыны ташла, алар ясаган нәрсәләрнең бөтенесен йотып бетерсен. Алар ясаган ул әйберләр – һичшиксез, сихерче хәйләсе. Сихерче исә кая барса да (нишләсә дә), уңышка ирешмәс”»** («Та-һә», 66–69).

Шуннан соң Муса галәйһис-сәләәм үз-үзен бер йодрыкка туплый. Эчендәге курку юкка чыга:

فَلَمَّا أَلْقَواْ قَالَ مُوسَى مَا جِئْتُمْ بِهِ السِّحْرُ إِنَّ اللَّهَ سَيُبْطِلُهُ إِنَّ اللَّهَ لَا يُصْلِحُ عَمَلَ الْمُفْسِدِينَ

**«Алар (җепләрен) ташлагач, Муса әйтте: “Сез китергән нәрсә – сихер. Һичшиксез, Аллаһ аны юк итәчәк. Һичшиксез, Аллаһ бозыклык таратучыларның эшен төзәтми”»** («Йунус», 81).

Аяти кәримәдән аңлашылганча, сихерчелек яки күз буу, бозымчылык – бары алдау, тышкы матурлау, кеше араларын бозудан гына гыйбарәт.

فَأَلْقَى مُوسَى عَصَاهُ فَإِذَا هِيَ تَلْقَفُ مَا يَأْفِكُونَ

**«Муса да таягын ташлады, һәм кинәт ул алар уйлап чыгарган нәрсәләрне йотты!»** («әш-Шугара», 45).

وَأَوْحَيْنَا إِلَى مُوسَى أَنْ أَلْقِ عَصَاكَ فَإِذَا هِيَ تَلْقَفُ مَا يَأْفِكُونَ

**«Без Мусага: “Таягыңны ыргыт!” – дип вәхи иттек. (Ни күрсеннәр), ул аларның уйдырма нәрсәләрен йота!»** («әл-Әгъраф», 117).

**Сихерчеләрнең сәҗдәгә каплануы**

Сихерчеләр Фиргавен һәм Мисыр халкы күз алдында җиргә берничә таяк һәм җепләр ыргыта. Алар да, боргаланып-сыргаланып, елан булып күренә башлый. Ләкин Муса галәйһис-сәләәм илаһи әмер белән таягын ыргыткач, ул галәмәт зур аждаһага әйләнеп, мәйдандагы бөтен сихер нәрсәләрен йотып җибәрә. Сихерчеләр бу хәлнең бәндәчел сәнгать һәм осталык түгел, ә илаһи бер могҗиза икәнлеген аңлый, чөнки сихер булса, җиргә ыргытылган таяклар һәм җепләр, сихер бозылгач, шул җирдә калыр иде. Хәлбуки, сихерчеләрнең

күз бууы бозылып, кире кагылып кына калмый, шул ук вакытта таяк белән җепләр дә бөтенләй юкка чыга:

فَوَقَعَ الْحَقُّ وَبَطَلَ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ

**«Хак ачыкланды һәм алар кылганнар ялган булды (юкка чыкты)»** («әл-Әгъраф», 118).

Муса галәйһис-сәләәмнең таягы сихерчеләрнең сихер коралларының барысын да йота, тик таякның үзендә бернинди дә үзгәреш килеп чыкмый. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү бу эшнең нindидер бәндәчел һөнәр булмыйча, киресенчә, илаһи кодрәт чагылышы икәнлеген сихерчеләргә күрсәтүне максат итеп куя. Чөнки ул чакта сихерчеләр эшләгән нәрсәләр бәндәчел һөнәр һәм сәләткә нигезләнгән кайбер күз буу уеннарыннан гыйбарәт була. Муса галәйһис-сәләәм таягында чынга ашырылган гайре табигый вакыйга – Аллаһ Тәгалә кодрәтенең бер күренеше ул. Шуңа күрә Хак Тәгалә сихерчеләрнең һәр заман башкарылып килгән һөнәрләрен юкка чыгара.

Хәзрәти Мусаның кешеләргә хас оста һөнәр иясеме, әллә күкләрдән иңдерелгән кодрәт тарафыннан ярдәмгә таянучымы икәнлеген аңларга теләп, сихерчеләрнең башлыгы дусларыннан берсенә: «Бу эшләр эшләнгәндә, Мусага игътибар белән карап тор әле, бу мизгелдә ул нинди халәттә булыр икән?» – дип сүз ката. Дусты ул әйткәнчә эшли. Муса галәйһис-сәләәмнең халәтен, үз-үзен тотышын бик җентекләп күзәтә. Вазгыятьне баш сихерчегә ул: «Әлеге вакыйга барышында Мусаның төсе китте, йөзе сулды. Үзе бер читтә Аллаһтан курку эчендә, илаһи манзараны күреп басып торган вакытта, таяк бер якта эшен дәвам итә иде», – дип аңлатып бирә. Бу хакта ишеткәч, сихерчеләрнең башлыгы болай дип нәтиҗә ясый: «Алайса бу күренеш – Аллаһтандыр, Муса эше түгел. Чөнки сихерче үз сихереннән курыкмас. Һичбер сәнгатькяр дә үз иҗатыннан курыкмас, киресенчә, аны бик җиңел һәм рәхәтлек белән башкарыр».

Бу сүзләрне әйткән сихерчеләр башлыгы соңыннан Муса галәйһис-сәләәмнең хак Пәйгамбәр булганлыгына иман китерә. Башка сихерче дуслары да аңа иярә һәм иман нуры белән шәрәфләнә (Габдулкадыйр Гәйлани, «әл-Фәтхур-Раббани», 38 б.).

Коръәни-Кәримдә бу хакта болай хәбәр ителә:

فَأُلْقِيَ السَّحَرَةُ سَاجِدِينَ. قَالُوا آمَنَّا بِرَبِّ الْعَالَمِينَ. رَبِّ مُوسَى وَهَارُونَ.
قَالَ آمَنْتُمْ لَهُ قَبْلَ أَنْ آذَنَ لَكُمْ إِنَّهُ لَكَبِيرُكُمُ الَّذِي عَلَّمَكُمُ السِّحْرَ فَلَسَوْفَ
تَعْلَمُونَ لَأُقَطِّعَنَّ أَيْدِيَكُمْ وَأَرْجُلَكُمْ مِنْ خِلَافٍ وَلَأُصَلِّبَنَّكُمْ أَجْمَعِينَ

**«(Әнә шул могҗизаны күргәч,) сихерчеләр сәҗдә кылучылар хәлендә капланды. Һәм әйттеләр: "Без бөтен галәмнәрнең Раббысына иман китердек. Мусаның һәм Һарунның Раббысына". (Ачудан күзе тонган Фиргавен) әйтте: "Мин сезгә рөхсәт бирмәс борын, сез аңа иман иттегез. Һичшиксез, ул – сезгә бу сихерне өйрәтүчегез. Әмма тиздән (сезне нишләтәчәгемне күрәчәксез һәм) беләчәксез! Кулларыгызны һәм аякларыгызны төрле яктан чабачакмын, аннары бөтенегезне дә асачакмын"»** («әш-Шугара», 46–49).

Бүтән аяти кәримәдә бу вакыйга менә болай телгә алына:

قَالَ آمَنْتُمْ لَهُ قَبْلَ أَنْ آذَنَ لَكُمْ إِنَّهُ لَكَبِيرُكُمُ الَّذِي عَلَّمَكُمُ السِّحْرَ فَلَأُقَطِّعَنَّ أَيْدِيَكُمْ
وَأَرْجُلَكُمْ مِنْ خِلَافٍ وَلَأُصَلِّبَنَّكُمْ فِي جُذُوعِ النَّخْلِ وَلَتَعْلَمُنَّ أَيُّنَا أَشَدُّ عَذَابًا وَأَبْقَى

**«(Фиргавен) әйтте: "Мин сезгә рөхсәт бирүдән алда сез аңа иман иттегез! Һичшиксез, ул – сезгә бу сихерне өйрәткән сезнең башлыгыгыз. Мин сезнең кулларыгызны һәм аякларыгызны чалыштырып чабып өзәчәкмен, шуннан соң сезне хөрмә кәүсәсенә кагып куячакмын. Менә шулвакыт кайсыбызның (газабы) көчлерәк һәм дәвамлырак икәнен белерсез!"»** («Та-һә», 71).

Теге яки бу мәнфәгатьләргә таянган берлек-берләшмәнең гомере дә шул мәнфәгать белән чикләнгән. Сихерчеләр иманга килмичә, Фиргавенне яклауларын дәвам итсәләр, Фиргавен каршында үз кешеләргә әйләнеп, бәлки нигъмәтләр эчендә йөзеп яшәрләр иде. Ләкин күңелләре иман нурына ачылып, үзләренә һидәят бирелгәч, фани, ягъни вакытлы ләззәткә караганда, бакый булган мәңгелек нигъмәткә өстенлек бирәләр һәм Фиргавеннең янауларына каршы анык ризасызлыкларын белдерәләр:

قَالُوا لَنْ نُؤْثِرَكَ عَلَى مَا جَاءَنَا مِنَ الْبَيِّنَاتِ وَالَّذِي فَطَرَنَا فَاقْضِ
مَا أَنْتَ قَاضٍ إِنَّمَا تَقْضِي هذِهِ الْحَيوةَ الدُّنْيَا

**«Әйттеләр: "Безгә килгән ачык могҗизаларга һәм безне юктан бар кылган Ул Затка каршы сине сайламаячакбыз. Син карар биргән нәрсәңә хөкем ит. Син дөнья тормышында гына хөкем итәсең"»** («Та-һә», 72).

قَالُوا لَا ضَيْرَ إِنَّا إِلَى رَبِّنَا مُنْقَلِبُونَ

**«Әйттеләр: "Бер зарар да юк! Һичшиксез, без Раббыбызга кайтачакбыз", – дип сүзләрен дәвам итәләр»** («әш-Шугара», 50).

Ник дигәндә, кул-аякларның чалыштырып киселүе бары бу фани дөньяга гына хас бер газап булып тора. Тән – ахыр нәтиҗәдә туфракка биреләчәк

бер корбан гына. Бәдәнгә – фанилык, җанга исә мәңгелек (чиксезлек) хас. Фани нәрсә бакый булганнан өстен чыга алмый. Шуңа күрә дә сихерчеләр, аермачык могҗизаларны күргәч, аятьтә бәян ителгәнчә, Фиргавенгә ул һич көтмәгән мөнәсәбәт күрсәтеп: «Синең золымың безгә зыян сала алмас! Синең зарарың бу дөньяга гына карый. Ахирәт бәхете исә мәңгелек!» – дип әйтәләр.

Сүзләрен дәвам итеп, болай диләр:

إِنَّا آمَنَّا بِرَبِّنَا لِيَغْفِرَ لَنَا خَطَايَانَا وَمَا أَكْرَهْتَنَا عَلَيْهِ مِنَ السِّحْرِ وَاللَّهُ خَيْرٌ وَأَبْقَى

**«Һичшиксез, хаталарыбызны һәм син көчләп кылдырган сихерчелегебезне гафу итсен, дип, Раббыбызга иман китердек. Аллаһ (әҗере) яхшырак, (җәзасы) дәвамлырак»** («Та-һә», 73).

إِنَّا نَطْمَعُ أَنْ يَغْفِرَ لَنَا رَبُّنَا خَطَايَانَا أَنْ كُنَّا أَوَّلَ الْمُؤْمِنِينَ

**«Без иман китерүчеләрнең тәүгеләре булдык, дип, Раббыбыздан безнең өчен хаталарыбызны ярлыкавын өмет итәбез»** («әш-Шугара», 51).

Аннары исә Җәнабел-Хакка ялваралар:

رَبَّنَا أَفْرِغْ عَلَيْنَا صَبْرًا وَتَوَفَّنَا مُسْلِمِينَ

**«...И, Раббыбыз! Өстебезгә (күп-күп) сабырлык бир һәм безне мөселманнар буларак вафат кыл!»** («әл-Әгъраф», 126).

Кыскасы, иртән кяфер зат буларак ярышка чыккан сихерчеләр кыска гына вакыттан соң, аяк-куллары кистерелеп, барысы да мөэмин, шәһид һәм әүлия булу хөрмәтенә ирешеп, Җәнабел-Хак белән кавышалар.

Сихерчеләр белән Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм арасында килеп чыккан бу вакыйга Коръәни-Кәримдә тәртип, сүз сөреше ягыннан кайбер аермалыклар белән дүрт аерым сүрәдә искә алына.[127] Бер тапкыр булган бу вакыйганың Коръәни-Кәримдә дүрт урында бәян кылынуы, һичшиксез, эчтәлегендәге бик күп серләр һәм хикмәтләр белән бергә, аның әһәмиятен дә ассызыклый.

Сихерчеләрнең авыр җәза-золым каршында үз-үзләрен тотышлары никадәр гыйбрәтле. Алар: «Йә, Раббы! Безне бу явызның золымыннан коткар!» – дип дога кылмыйлар, фани затларның җәбер-җәзасына сабыр итеп, мөселман булып җан бирү мөмкинлеген сорыйлар. Чөнки алар, иманнары мәсьәләсендә нининдидер зәгыйфьлеккә төшмичә, соңгы сулышларын иман белән алу өчен борчыла.

Соңгы сулыш белән бәйле буларак, Коръәни-Кәримдә:

127. Карагыз: «Әгъраф» сүрәсе, 109–126 нчы; «Йунус» сүрәсе, 76–82 нче; «Та-һә» сүрәсе, 56–73 нче; «Шугара» сүрәсе, 34–51 нче аятьләр.

يَٓا اَيُّهَا الَّذِينَ اٰمَنُوا اتَّقُوا اللّٰهَ حَقَّ تُقَاتِهِ وَلَا تَمُوتُنَّ اِلاَّ وَاَنْتُمْ مُسْلِمُونَ

**«И, иман китерүчеләр! Аллаһтан тиешенчә (Аңа ярарлык итеп) куркыгыз һәм мөселманнар булып кына үлегез!»** – дип әйтелә («Әли Гыймран», 102). Әлеге илаһи кисәтүне үтәүнең бердәнбер чарасы исә, тормышта Аллаһ һәм Аның Рәсүле күрсәткән хак юл белән барып, соңгы сулышта да Аллаһның рәхмәтенә ялвару хәлендә булудан гыйбарәт. «Сыйрати мүстакыйм» (туры юл) кушканча яшәп, шул хәлдә Җәнабел-Хак катына күчә алу юлы бер аяти кәримәдә болай дип искәртелә:

يَٓا اَيُّهَا الَّذِينَ اٰمَنُوا اِنْ تَنْصُرُوا اللّٰهَ يَنْصُرْكُمْ وَيُثَبِّتْ اَقْدَامَكُمْ

**«И, иман китерүчеләр! Сез Аллаһка (Аллаһның диненә) ярдәм итсәгез, Ул да сезгә ярдәм итәчәк һәм аяк табаннарыгызны нык итәчәк (тайдырмас)»** («Мөхәммәд», 7).

Мәүләна Җәләлетдин Руми хәзрәтләре бәян ителгән кыйсса белән бәйле рәвештә ишари мәгънәләр дә таба: «Сихерчеләр үлүл-газыйм пәйгамбәргә, Аллаһка якын олуг бәндәгә, аның өстенлеген танып, бәйге башында күрсәткән илтифат һәм хөрмәт, нәзакәтле мөнәсәбәт бәрәкәте белән тәүхид гакыйдәсенә килделәр, фәкать шул бөек пәйгамбәр белән ярышка чыгулары сәбәпле җәзага тарыдылар».

Чыннан да, сихерчеләрнең Хәзрәти Мусага карата бераз гына булса да хөрмәт-илтифат күрсәтүләре күңелләрендә иман нурына ачылган бер тәрәзә һәм һидәяткә этәргеч була. Чөнки лаеклы затка мәхәббәт һәм ачу-нәфрәт уяткан бәндәгә карата дошманлык хисе тормышны мөмкин кадәр югары күтәргән фактор булып тора.

Хәзрәти Мәүләна Җәләлетдин Руми әлеге вакыйганың эчке асылына түбәндәгечә аңлатма бирә:

«Мәлгунь һәм залим Фиргавен сихерчеләрне, иманга килгәннәре өчен, үлем белән куркытып яный-яный: “Кулларыгызны һәм аякларыгызны чалыштырып чабып өзәчәкмен. Аннары сезне гафу итмичә, астырачакмын!” – дигән иде. Фиргавен ул вакытта сихерчеләр куркыр, котлары очып, калтырый-калтырый аңа буйсынырлар, дип уйлаган иде. Әмма Фиргавен ул сихерчеләрнең курку-борчылудан котылганын, илаһи серләр һәм хикмәтләргә ирешкәнен белми иде шул. Алар күк килесендә йөз тапкыр төелеп, он хәленә килсәләр дә, инде шәүлә белән үзләрен аерырлык гыйлем һәм аң-зиһенгә ия булуларын күрсәткәннәр иде (Ягъни җанның – төп асыл, ә бәдәннең исә бер шәүлә, күләгә генә икәнен аңлаганнар һәм шуннан бер мизгел генә әүвәлрәк бу күләгәне корбан итеп, үз асылларына кайтканнар, “фәна фәллаһ” (дөньялыктан тәмам ваз кичеп, Аллаһка йөз тоту) дәрәҗәсенә ирешкәннәр)».

«И, кеше! Бу дөнья йокы белән төштән гыйбарәт. Син андагы әйлән-бәйләннәргә һәм тамашаларга алданма! Әгәр төшеңдә кулың киселсә яки тәнең кисәк-кисәк итеп туралса да, курыкма! Чөнки: “Бу дөнья бер төш кенә ул!” – дип әйтелгән».

**Машыйта хатын**

Фиргавен кызының хезмәтчесе була ул. Беркөнне Фиргавен кызының чәчләрен тарар өчен тарак алганда, «бисмиллаһ»ны әйтә. Моны ишетеп, кыз шундук әтисенә әләкләргә йөгерә. Фиргавен кичекмәстән Машыйта хатынны үз янына чакырып, бу хәлгә аңлатма таләп итә. Машыйта исә, күңелендәге иман дәрте белән кыюланып, Фиргавенгә: «Син дә безнең кебек бер фани нәрсә! Ничек инде син тәңре була аласың?!» – дип белдерә.

Фиргавен бик кызып китә: «Димәк, син дә Мусага иман китергәнсең, аңа ияргәнсең, шулаймы?!» – дип ачулана. Аннары исә әкренләп Машыйта хатынны җәзалый-газаплый башлый. Ләкин һичнигә карамастан, Машыйта хатын тәүхид гакыйдәсеннән баш тартмый. Шуннан соң Машыйта хатынның алдына аның биш яшьлек кызын алып киләләр. «Әгәр Фиргавенне тәңре дип танымасаң, кызыңның бугазын кисәчәкбез!» – дип яныйлар.

Машыйта хатын барыбер иманын сатмый. Аннары кызын әнисенең күз алдында үтереп, каннарын Машыйта хатынның йөзенә сылыйлар. Ул бик олуг мәхәббәт һәм Аллаһка бирелгәнлектән, транс хәлендә һаман да: «Аллаһ – бер! Аллаһ – бердәнбер! Муса – Аның рәсүле!» – дип кабатлый.

Фиргавен һәм аның яраннары ачудан шартлый яза. Бу юлы аның өч айлык баласын китертеп, әнисенә сузалар. Сабый, имү өчен, әнисенең күкрәген эзли башлый. Залимнәр аны шундук кире тартып ала да: «Әгәр сүзләреңнән ваз кичмәсәң, бу балаңны мичкә атачакбыз!» – диләр.

Машыйта хатын, бу газапка да сабыр итеп, иманыннан баш тартмый. Ахыр чиктә өч айлык сабыен мичкә ташлыйлар. Риваятькә күрә, нарасый, ут телләре арасында телгә килеп, болай дип дәшә: «Әнкәем, иманыңнан ваз кичә күрмә, сабыр ит! Җәннәт белән синең арада бер адымлык юл калганын күрәм!..»

Ниһаять, Машыйта хатын шәһид китә һәм җәннәттәге балалары янына юнәлә.

Түбәндәге хәдис-шәрифтә Машыйта хатын искә алына:

«Үбәй ибне Кәгъб радыйаллаһу ганһе сөйләвенчә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мигъраҗ кичәсендә бик тәмле хуш ис сизә дә: *“И, Җәбраил, нинди хуш ис бу?”* – дип сорый. Җәбраил галәйһис-сәләәм: “Бу – Машыйта хатынның, аның ике баласының һәм иренең кабер исе”, – дип әйтә» (Ибне Мәҗә, «Фитән», 23/4030).

**Асия анабызның шәһид китүе**

Фиргавеннең Машыйтага карата кылган явызлыгыннан соң, Асия анабыз аңа бик үпкәли, ачулана, хәтта аны дәшми-сөйләшмичә түбәнсетә. Шуннан соң Фиргавен Асия анабызның да Муса галәйһис-сәләәмгә иман китергәнен аңлап ала. Асия анабыз исә бу хакыйкатьне башка яшереп тормый һәм: «Әйе, мин дә Мусаның Раббысына иман китердем!» – дип, Фиргавеннең шикләрен раслый.

Риваять кылынганча, Фиргавен Асияне, аркасына яткырып, дүрт терәк баганага бәйләтә. Өстенә бер тегермән ташы куйдыра. Шул рәвешле төрле явызлыклар кыла, төрлечә җәфалый. Бервакыт Муса галәйһис-сәләәм, газаплау-җәзалау мәйданыннан узганда, Асия анабызның авыр җәзаланганын күрә. Газапларының бик авырлыгын белдерер өчен, Асия анабыз Хәзрәти Мусага ым кага. Пәйгамбәр зат дога кылгач, Асия анабыз авырту-газапларны тоймас хәлгә килә.

Башка бер риваятькә күрә, Асия анабызны бик эссе чүлгә чыгарып ташлыйлар. Фәрештәләр аңа күләгә ясый. Ахыр чиктә Асия анабыз әнә шул рәвешле шәһид китә. Коръәни-Кәримдә ул мактап телгә алына:

وَضَرَبَ اللَّهُ مَثَلًا لِلَّذِينَ آمَنُوا اِمْرَأَةَ فِرْعَوْنَ إِذْ قَالَتْ رَبِّ ابْنِ لِي عِنْدَكَ
بَيْتًا فِي الْجَنَّةِ وَنَجِّنِي مِنْ فِرْعَوْنَ وَعَمَلِهِ وَنَجِّنِي مِنَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ

**«Аллаһ иман китерүчеләр өчен Фиргавеннең хатынын (Асияне) үрнәк итеп китерә. Менә ул: "И, Раббым! Җәннәттәге хозурыңда минем өчен бер өй сал! Мине Фиргавеннән һәм аның (яман) гамәленнән коткар! Залим кешеләрдән дә мине коткар!" – дигән иде»** («әт-Тәхрим», 11).

Риваятьтә тапшырылганча, Асия анабыз бу доганы үзен җәзалаган чакта укый. Шулвакыт аңа: «Башыңны күтәр!» – дигән илаһи әмер килә. Башын күтәреп, күккә карагач, күзен каплаган элпә-пәрдә юкка чыгарылып, аның өчен җәннәттә корылып яткан ак энҗеле сарай күрсәтелә. Хәзер инде ул, бернинди дә авырту тоймыйча, елмаеп, сараена карап тора.

Асия анабызның фазыйләтләреннән берсе буларак, Сөләйман Чәләби Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәллә туган вакытта, аның шунда көтеп торуы, фәрештәләр һәм хур кызлары белән бергә Хәзрәти Әминәне котлавы турында яза:

«Асия иде нурлы, ай йөзле,

Әйттеләр: "Улың кебек матур язмышны,

Бирмәгән Җәлил бер анага да"».

**Манара**

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм тәүхид гакыйдәсен тараткан саен, мөэминнәрнең саны күбәя, моңа нисбәтле Фиргавеннең дә нәфрәте һәм явызлыгы арта бара. Ул бик зур манара төзетә. Бу манара ат белән менә торган итеп ясала. Аның төзелеше җиде елда тәмамлана.

Ахмак Фиргавен бу манараның түбәсенә менеп, имеш, Мусаның Раббысы белән көрешәчәк! Тәүхид гакыйдәсен белмәгәнгә күрә, аның Аллаһ турында күзаллаулары бәндәчел дөньядагы предметларга, формаларга, ягъни антропоморфик фикерләүгә таяна. Бу исә Аллаһны билгеле бер шәкелдә күзаллаган караш була. Шул ук вакытта ул заманда, грек диннәрендәге кебек, күпаллалык та яши, бәндәләр җир тәңресе, күк тәңресе, мәхәббәт алласы һ.б. шундыйларга табына.

Фиргавен, бу манарадан күккә карап, халыкка Мусаның Раббысын очратмавы турында хәбәр таратырга җыена яки: «Без шулкадәр көч-куәтебез, мөмкинлекләребез һәм мәдәниятебез белән күкләргә юл табып та ирешә алмаганда, Муса ничек менсен дә безгә хәбәр китерсен инде!» – кебек томана фикерләре белән җәмгыятьтә фетнә чыгарырга маташа.

Аяти кәримәдә әйтелә:

وَقَالَ فِرْعَوْنُ يَا هَامَانُ ابْنِ لِي صَرْحًا لَعَلِّي أَبْلُغُ الْأَسْبَابَ.
أَسْبَابَ السَّمَوَاتِ فَأَطَّلِعَ إِلَى إِلَهِ مُوسَى وَإِنِّي لَأَظُنُّهُ كَاذِبًا وَكَذَلِكَ زُيِّنَ
لِفِرْعَوْنَ سُوءُ عَمَلِهِ وَصُدَّ عَنِ السَّبِيلِ وَمَا كَيْدُ فِرْعَوْنَ إِلَّا فِي تَبَابٍ

**«Фиргавен әйтте: “И, Һаман! Миңа бер бина (манара) сал. Бәлки, мин юлларга ирешермен. Күкләрнең юлларына ки, Мусаның илаһына карый алырмын. Гәрчә, һичшиксез, мин аны бер ялганчы, дип саныйм”. Начар гамәле Фиргавенгә шулай бизәп күрсәтелде, ул юлдан чыгарылган булды. Фиргавеннең хәйләсе бушка чыкты»** («әл-Мүэмин», 36–37).

Риваятькә күрә, Аллаһ Тәгаләдән фәрман килгәч, Җәбраил галәйһис-сәләәм манарага канаты белән суга. Бина өч кисәккә аерыла. Меңнәрчә гаскәр кырыла. Кирпеч һәм чирәп яндыручылар үз утларында көлгә әйләнә.

Бу юлы да уңышсызлыкка очрагач, Фиргавеннең ачуы тагын да көчәя, ул тагын да явызлана. Кыптыйларның сыптыйларга карата золымы бөтен чикләрне аша:

وَقَالَ الْمَلَأُ مِنْ قَوْمِ فِرْعَونَ أَتَذَرُ مُوسَى وَقَوْمَهُ لِيُفْسِدُوا فِي الْأَرْضِ وَيَذَرَكَ
وَآلِهَتَكَ قَالَ سَنُقَتِّلُ أَبْنَاءَهُمْ وَنَسْتَحْيِي نِسَاءَهُمْ وَإِنَّا فَوْقَهُمْ قَاهِرُونَ

**«Фиргавеннең кавеменнән олуглары әйтте (Фиргавенгә): “Мусаны һәм аның кавемен бу туфракта бозыклык таратсыннар һәм ул сине дә, илаһларыңны да ташласын, дип калдырасыңмы?”» Ул әйтте: «Аларның ир балаларын үтертербез, хатыннарын исә исән калдырырбыз. Һичшиксез, без алар өстеннән какшамас көчкә иябез»** («әл-Әгъраф», 127).

Бәни Исраил кавеме бу хәл турында Муса галәйһис-сәләамгә зарлана. Ул исә сабыр булырга киңәш бирә:

قَالَ مُوسَى لِقَوْمِهِ اسْتَعِينُوا بِاللَّهِ وَاصْبِرُوا إِنَّ الْأَرْضَ
لِلَّهِ يُورِثُهَا مَنْ يَشَاءُ مِنْ عِبَادِهِ وَالْعَاقِبَةُ لِلْمُتَّقِينَ.

**«Муса кавеменә әйтте: “Аллаһтан ярдәм сорагыз һәм сабыр булыгыз. Һичшиксез, җир – Аллаһныкы гына. Ул колларыннан теләгәннәрен аңа варис итәр. Ахыр исә тәкъвалык ияләренә (Аллаһтан куркып, гөнаһтан тыелучыларга)”»** («әл-Әгъраф», 128).

Ләкин кавеме Муса галәйһис-сәләамгә бераз кирелек күрсәтә башлый. Алар пәйгамбәрләренә даими авырлык китерә, сабырсызлана, күп эшләрдә кабалана. Чөнки халык материалистик караш белән яшәгән була:

قَالُوا أُوذِينَا مِنْ قَبْلِ أَنْ تَأْتِينَا وَمِنْ بَعْدِ مَا جِئْتَنَا قَالَ عَسَى رَبُّكُمْ
أَنْ يُهْلِكَ عَدُوَّكُمْ وَيَسْتَخْلِفَكُمْ فِي الْأَرْضِ فَيَنْظُرَ كَيْفَ تَعْمَلُونَ

**«Әйттеләр: “Син безгә (пәйгамбәр буларак) килмәс борын да, син безгә килгәннән соң да, без хәсрәт чиктек”». (Муса) әйтте: «Раббыгыз дошманыгызны һәлак итәр һәм җирдә сезне алар урынына куяр, аннары ничек гамәл кылачагыгызны карар өчен»** («әл-Әгъраф», 129).

Шул рәвешле Аллаһ киләчәкнең иман китерүчеләр кулында булачагына ишарәли.

Кыптыйлар золым кылуларын дәвам итә. Хәзрәти Муса бу явызлыклар бетсен өчен дога кыла. Бер-бер артлы илаһи галәмәтләр туып, кыптый кавеме өстенә чиратлашып төрле бәла-казалар ява башлый:

وَلَقَدْ أَخَذْنَا آلَ فِرْعَونَ بِالسِّنِينَ وَنَقْصٍ مِنَ الثَّمَرَاتِ لَعَلَّهُمْ يَذَّكَّرُونَ.
فَإِذَا جَاءَتْهُمُ الْحَسَنَةُ قَالُوا لَنَا هذِهِ وَإِنْ تُصِبْهُمْ سَيِّئَةٌ يَطَّيَّرُوا بِمُوسَى
وَمَنْ مَعَهُ أَلَا إِنَّمَا طَائِرُهُمْ عِنْدَ اللهِ وَلَكِنَّ أَكْثَرَهُمْ لَا يَعْلَمُونَ

**«Үгет алсыннар, дип, Без Фиргавен гаиләсен елгалар һәм җимешләрнең кимүе белән тоттык (җәзаладык). Аларга бер яхшылык (муллык)**

**килсә: “Бу безнеңөчен”, – дияләр иде. Әгәр бер начарлык килсә, Муса һәм аның янындагылардан шомлана иделәр. Һичшиксез, аларның шомланулары Аллаһ – хозурында. Ләкин аларның күпчелеге (моны) белми»** («әл-Әгъраф», 130–131).

**Могҗизалар**

وَقَالُوا مَهْمَا تَأْتِنَا بِهِ مِنْ آيَةٍ لِتَسْحَرَنَا بِهَا فَمَا نَحْنُ لَكَ بِمُؤْمِنِينَ. فَأَرْسَلْنَا عَلَيْهِمُ الطُّوفَانَ وَالْجَرَادَ وَالْقُمَّلَ وَالضَّفَادِعَ وَالدَّمَ آيَاتٍ مُفَصَّلَاتٍ فَاسْتَكْبَرُوا وَكَانُوا قَوْمًا مُجْرِمِينَ

**«(Алар Мусага) әйттеләр: “Безне сихерләү өчен нинди генә аять (могҗиза) китерсәң дә, без сиңа ышанмаячакбыз”. Без аларга аерым-аерым аятьләр (могҗизалар) итеп туфан, чикерткәләр, хәшәрәтләр, гөберле бакалар һәм кан җибәрдек. Әмма алар тәкәбберләнделәр һәм гөнаһлы кавем булдылар»** («әл-Әгъраф», 132–133).

Газапка тарыгач, кыптыйлар Хәзрәти Мусага: «И, олуг галим!» – дип мөрәҗәгать итә. Бәла-казалар үтеп китүгә, янә буйсынмый башлыйлар, киреләнеп: «Чынлыкта, бу – вакытлы гына иде», – дип сөйләнәләр.

Бәла-казалар, асылда, золымнар иң югары дәрәҗәгә җиткән вакытта килә башлый. Аяти кәримәдә белдерелгәнчә, кыптыйларның явызлыгы көчәя барып, ачу-нәфрәтләре иң зур дәрәҗәгә ирешкәч, алар өстенә күп-күп авырлыклар җибәрелә.

**1. Туфан**

Аллаһ Тәгалә бик көчле яңгырлар яудыра. Шул дәрәҗәдә көчле ки, кыптыйларның өйләренә су тула. Су муеннарына кадәр күтәрелә, утырып торган кеше, басмаса, тончыгып, батып үлә. Алар тәмам һәлак булыр хәлгә җитә. Ләкин сыптыйларга бернинди дә зыян килми.

Кыптыйлар шундук Муса галәйһис-сәләәм янына йөгерә: «И Муса! Раббыңа дога кылчы, әгәр бу бәла чигенсә, иманга киләчәкбез һәм синең белән кавемеңне ректә калдырачакбыз», – диләр.

Муса галәйһис-сәләәм дога кылгач, сулар чигенә. Аннары бик иркенлек, муллык заманы килә. Кыптыйлар янә иманга килүгә каршы чыга: «Бу сулар безгә газап түгел, нигъмәт икән бит! Чынлыкта, алар вакытлы гына булган! Бу хәлгә Муса догасының һич катнашы юк!» – дип белдерәләр.

**2. Саранча**

Күпмедер вакыттан соң Хак Тәгалә саранча (чикерткә) көтүләре җибәрә. Алар Аллаһ биргән муллыкны кырып-себереп ашап, бар нәрсәне харап итәләр.

Тик Исраил угылларына һич зарарлары тими. Кыптыйлар янә Хәзрәти Мусага килеп җитә: «И галим зат! Дога кылчы! Бу бәладән котылсак, сиңа иман китерәчәкбез, синең сүзләреңне кабул итәчәкбез!» – ди алар.

Муса галәйһис-сәләәм дога укуга, илаһи газап туктый. Әмма өсләреннән газап богавы төшкәнен күреп, иркен сулаган кыптыйлар янә сүзләрендә тормый – золым һәм буйсынмауларын дәвам итәләр.

### 3. Бет-борчалар

Шуннан соң Җәнабел-Хак аларны бет һәм борчалар белән җәфалый. Ризык ашаганда, савытлар бет-борчалар белән тула. Бу бик зур бәлагә әйләнә. Янә Муса галәйһис-сәләәм янына чабып киләләр. Хәзрәти Муса дога кылгач, бу газаптан да котылалар. Фәкать монысында да Аллаһ дненегә буйсынырга теләмиләр.

### 4. Гөберле бакалар

Бу юлы Муса галәйһис-сәләәм Нил елгасы янына бара. Таягы белән сугуга, бөтен гөберле бакалар Мисырны басып ала. Һәр җир, хәтта ашамлык савытларына кадәр бакалар белән тула. Кыптыйлар кабат Муса галәйһис-сәләәм янына килә: «И галим зат! Инде чын-чынлап үкенәбез. Сезне Изге җирләргә (Иерусалимгә) җибәрәбез!» – дип вәгъдә итәләр. Тик Муса галәйһис-сәләәмнең догасы ярдәмендә бәладән котылгач, үзләрен тагын искечә тота башлыйлар.

### 5. Кан

Кыптыйлар һич ипкә килмәгәч, Аллаһ Тәгалә Нил елгасын канга әйләндерә. Халык эчәр су таба алмас хәлгә җитә. Нил елгасы сыптыйлар эчкәндә һәм кулланганда, асыл саф-чиста килеш кала, кыптыйлар өчен исә кып-кызыл канга әйләнә. Башбирмәс халык Муса галәйһис-сәләәмгә килеп ялвара. Бу бәла дә алардан алып ташлана. Ләкин ялганчы һәм рәхмәтсез кыптыйлар иманга килүдән кабат баш тарта.

Мәүләна Җәләлетдин Руми Нил елгасының канга әверелү вакыйгасын «Мәснәви»ендә матур тел белән шундый үтемле тасвирлый:

«Бер кыптый эсселектән куырылып, бер сыптыйның өенә килә. “Мин синең дустың һәм туганың. Бүген сиңа бик мохтаҗ хәлдәмен. Үзең өчен Нилдән бер касә су тутыр да, бу иске дустың, синең кулыңнан су эчсенче! Үзең өчен тутырсаң, касәдәге су кан булмас. Саф һәм сихердән азат булыр”, – дип бик озак ялвара ул.

Сыптый исә, кыптый могҗизаны аңласын өчен, Нилдән бер касә су тутырып ала. Авызына китереп, яртысын үзе эчә. Касәне: “Әйдә,эч!” – дип кыптыйга суза.

Кыптый, сөенә-сөенә, касәне авызына тидерә, ләкин су кып-кызыл канга әйләнә. Шуннан соң сыптый касәне үзенә ала. Кан кабат саф су хәленә кайта. Кыптый бик үпкәли, ачуы басылганчы утырып торгач, сыптыйга таба борыла: "Әй, туган! Бу мәсьәләнең чишелеше бармы, нинди? Моның нинди сере бар?" – дип сорый ул.

Сыптый аңлатып бирә: "Нилнең шушы татлы һәм чиста суын Мусаның диненә инанганнар гына эчә ала. Син дә Фиргавен тарафыннан ваз кичеп, Муса юлына аяк бассаң, әнә шулчакта бу суның чисталыгын һәм ләззәтен татый алырсың!". Кыптыйга нәсыйхәтен дәвам итеп, сыптый болай ди: "Ай белән солых кор да, тулган айны күрерсең!" (Монда ай, дигәндә, Муса галәйһис-сәләәм күздә тотыла; тулган ай исә пәйгамбәрнең могҗизасын белдерә).

"Аллаһның ихлас колларына каршы ачу-нәфрәт сине сукыр һәм чукрак итеп, ике арага меңнәрчә пәрдә тарткан! Адашу һәм көферлек үзәнендә сукырларча йөреп, хакыйкатьне күрми каласың! Тау кадәр көферлегеңне тәүбә белән эрет, һидәят табарсың! Шулчакта Хак Тәгаләне танучылар касәсеннән син дә үз өлешеңне татый алырсың!

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Нил суын кяферләргә хәрәм кылган икән, син ниндидер хәйлә белән, ягъни мине шул хәйлә коралы итеп кулланып, аны ничек эчә аласың инде? И, кыптый! Ничек инде Нил куелган чикне бозып, илаһи әмерне кире каксын да, кяферләр өчен су булсынмы!.."»

Шундый искиткеч күренешләр каршында:

وَقَالَ فِرْعَوْنُ ذَرُونِي أَقْتُلْ مُوسَى وَلْيَدْعُ رَبَّهُ إِنِّي أَخَافُ
أَنْ يُبَدِّلَ دِينَكُمْ أَوْ أَنْ يُظْهِرَ فِي الْأَرْضِ الْفَسَادَ

**«Фиргавен (гаҗизлеккә төшкәч) әйтте: "Калдырыгыз мине, Мусаны үтерим, ул (коткара алса) Раббысына ялварсын, чөнки мин сезнең динегезне алмаштыруыннан (ягъни потпәрәстлектән баш тарттыруыннан) яки җирдә бозыклык чыгаруыннан куркамын"»** («әл-Мүэмин», 26).

Фиргавеннең мондый сүзләре аның Муса галәйһис-сәләәмне үтерергә теләвенә, ләкин әйләнә-тирәсендәгеләрнең бу эшкә комачаулавына ишарәле. «Ул син куркырлык зат түгел. Син бит тәңре! Әгәр аны үтерсәң, халык күңеленә бер шик кертәчәксең! Һәркем синең хакта Мусаның могҗизалары каршында гаҗиз, көчсез булып калды, дип уйлаячак...» – диләр Фиргавенгә.

Шул ук вакытта Фиргавеннең сүзләре аның Хәзрәти Мусадан никадәр курыкканлыгын да күрсәтә. Чынлыкта, Фиргавен Муса галәйһис-сәләәмнең пәйгамбәрлеген күңелдән таный, ләкин горурлыгы, тәкәбберлеге һәм сукырларча кирелеге иман китерүенә комачаулый.

Фиргавеннең үз-үзен тотышын күргәч:

وَقَالَ مُوسَى إِنِّي عُذْتُ بِرَبِّي وَرَبِّكُمْ مِنْ كُلِّ مُتَكَبِّرٍ لَا يُؤْمِنُ بِيَوْمِ الْحِسَابِ

**«Муса әйтте: “Һичшиксез, мин хисап көненә ышанмаган һәр тәкәбердән минем дә Раббым, сезнең дә Раббыгыз (булган Аллаһка) сыендым”»** («әл-Мүэмин», 27).

Югарыдагы аятькә нигезләнеп, кайбер тәфсир галимнәре могҗизадан соң да Фиргавеннең иманга килмәвендә хикмәт Муса галәйһис-сәләмнең менә шушы догасында ачыкланган дип белдерәләр. Сәбәпләр мондый:

а) Ахирәткә ышанмау;

б) Бик тәкәббер булу. Чөнки тәкәббер зат һәркемне үзеннән түбәнрәк итеп күрергә тели. Шунлыктан тәкәбберлек хәдис-шәрифтә зур гөнаһ буларак искә алына: *«Йөрәгендә гәрчич бөртеге кадәр иман булган зат җәһәннәмгә кермәс. Йөрәгендә гәрчич бөртеге кадәр тәкәбберлек булган зат исә җәннәткә керә алмас»* (Мөслим, «Иман», 147).

Күренгәнчә, иманның кыйммәте шулкадәр югары ки, шул иман ярдәмендә кеше илаһи ярлыкауга лаек булыр һәм гөнаһының кәффарәтен түләгәч, үтәгәч, җәннәт нигъмәтләренә ирешә алыр. Иблис сыйфаты булган тәкәбберлек исә шулкадәр яман ки, җәннәткә керергә комачауларлык дәрәҗәдә иманны көчсезләндерер.

Башка бер хәдис-шәрифтә болай дип әйтелә: *«Кемгәдер, гөнаһ алу өчен, мөселман кардәшен кимсетеп карау да җитә!»* (Мөслим, «Бирр», 32; Әбү Давыт, «Әдәб», 35; Тирмизи, «Бирр», 18).

Локман галәйһис-сәләмнең улына тәкәбберлек һәм масаючанлык белән бәйле нинди күркәм нәсыйхәт сөйләгән:

وَلَا تُصَعِّرْ خَدَّكَ لِلنَّاسِ وَلَا تَمْشِ فِي الْأَرْضِ مَرَحًا إِنَّ اللهَ لَا يُحِبُّ كُلَّ مُخْتَالٍ فَخُورٍ

**«Йөзеңне кешеләрдән чөермә, җирдә масаеп йөрмә. Һичшиксез, Аллаһ һәр масаеп йөргән, үзен яратучы (масаючан) кешене сөйми!»** («Локман», 18).

«Исра» сүрәсенең 37 нче аяти кәримәсендә болай дип әйтелә:

وَلَا تَمْشِ فِي الْأَرْضِ مَرَحًا إِنَّكَ لَنْ تَخْرِقَ الْأَرْضَ وَلَنْ تَبْلُغَ الْجِبَالَ طُولًا

**«Җирдә масаеп йөрмә. Һичшиксез, син җирне (авырлыгың һәм бөеклегең белән) яра алмассың, биеклектә тауларга ирешә алмассың!»**

Аллаһ Тәгалә тәкәбберлек һәм масаю сазлыгына баткан Фиргавенне һәм аның яраннарын җәзалавындагы хикмәтне түбәндәгечә ачыклый:

وَمَا نُرِيهِمْ مِنْ آيَةٍ إِلَّا هِيَ أَكْبَرُ مِنْ أُخْتِهَا وَأَخَذْنَاهُمْ بِالْعَذَابِ لَعَلَّهُمْ يَرْجِعُونَ

**«Без аларга бер аять (могҗиза) күрсәтә идек, һичшиксез, ул алдагысыннан олуграк иде. Һәм алар (туры юлга) кайтсыннар, дип, аларны газаплар белән тоттык»** («әз-Зухруф», 48).

Бәла-казалар белән тәрбияләнгән бу милләт, җәфа-газапка тарыганда, мескен бәрәнгә әйләнә, үзләренә җибәрелгән җәфалар туктатылгач, әйтерсең, ерткычка әйләнә. Аларның мондый икейөзлелекләре һәм сүзләрендә тормавы турында Аллаһ Тәгалә аяти кәримәләрдә дә хәбәр итә:

وَلَمَّا وَقَعَ عَلَيْهِمُ الرِّجْزُ قَالُوا يَا مُوسَى ادْعُ لَنَا رَبَّكَ بِمَا عَهِدَ عِنْدَكَ
لَئِنْ كَشَفْتَ عَنَّا الرِّجْزَ لَنُؤْمِنَنَّ لَكَ وَلَنُرْسِلَنَّ مَعَكَ بَنِي إِسْرَآئِيلَ

**«Бу газап аларга килгәч, алар: “И, Муса! Синең янында булган вәгъдә хөрмәтенә безнең өчен Раббыңа ялвар. Әгәр бу газапны бездән алсаң, без сиңа ышаначакбыз һәм Исраил улларын синең белән бергә, һичшиксез, җибәрәчәкбез”, – дип әйттеләр»** («әл-Әгъраф», 134).

وَقَالُوا يَا أَيُّهَا السَّاحِرُ ادْعُ لَنَا رَبَّكَ بِمَا عَهِدَ عِنْدَكَ إِنَّنَا لَمُهْتَدُونَ.
فَلَمَّا كَشَفْنَا عَنْهُمُ الْعَذَابَ إِذَا هُمْ يَنْكُثُونَ

**«(Муса мөрәҗәгать итеп) алар: “И, сихерче! Синең янында булган вәгъдәсе хөрмәтенә безнең өчен Раббыңа ялвар. Без һидәят тапкан (туры юлга кергән) кешеләр булырбыз”, – диделәр. Әмма без алардан газапны алгач, алар шундук (вәгъдәләрен) бозалар»** («әз-Зухруф», 49–50).

فَلَمَّا كَشَفْنَا عَنْهُمُ الرِّجْزَ إِلَى أَجَلٍ هُمْ بَالِغُوهُ إِذَا هُمْ يَنْكُثُونَ

**«Әмма Без ирешәчәкләре вакытына кадәр газапны алардан алгач, алар вәгъдәләрен боздылар»** («әл-Әгъраф», 135).

**Фиргавеннең хәйләле мескенләнүе**

Хәзрәти Мусаның могҗизалары каршында гаҗиз калган һәм халкының тәүхид диненә керүеннән курыккан Фиргавен Нил буенда бер чатыр кордыра. Ике ел буе шул тирәдән узып баручыларны: «Мусага ышанмагыз! Сез табынган илаһлар кебек мин дә сезнең Раббыгыз булам!» – дип өнди, үгетли.

وَنَادَى فِرْعَوْنُ فِي قَوْمِهِ قَالَ يَا قَوْمِ أَلَيْسَ لِي مُلْكُ مِصْرَ وَهذِهِ الْأَنْهَارُ تَجْرِي مِنْ
تَحْتِي أَفَلَا تُبْصِرُونَ. أَمْ أَنَا خَيْرٌ مِنْ هَذَا الَّذِي هُوَ مَهِينٌ وَلَا يَكَادُ يُبِينُ

**«Фиргавен кавеменә дәште һәм әйтте: “И, кавемем! Мисырның хакимияте миндә түгелме? Шушы елгалар минем астымнан ага түгелме?**

**Әллә күрмисезме? Юкса мин шушы түбән (зәгыйфь), (сүзен) көчкә аңлата алган кешедән яхшырак түгелме?”»** («әз-Зухруф», 51–52).

Фиргавен үзенең хакимияте, кодрәте, байлыгы һәм мәһабәтлелеген күрсәтергә тели, аның белән чагыштырганда, Муса галәйһис-сәләамнең теле тотлыга торган фәкыйрь һәм зәгыйфь зат икәнлеген белдерә:

فَلَوْلَا أُلْقِيَ عَلَيْهِ أَسْوِرَةٌ مِنْ ذَهَبٍ أَوْ جَاءَ مَعَهُ الْمَلَائِكَةُ مُقْتَرِنِينَ

**«Нишләп аңа алтын беләзекләр кидерелмәгән? Һәм нишләп аның белән бергә бер-берсенә бик якын торган фәрештәләр килмәгән?»** – дип, андый кешенең пәйгамбәр була алмаганлыгын расларга тырыша («әз-Зухруф», 53). Нәтиҗәдә:

فَاسْتَخَفَّ قَوْمَهُ فَأَطَاعُوهُ إِنَّهُمْ كَانُوا قَوْمًا فَاسِقِينَ

**«Ул (Фиргавен) кавеменнән үзенә итагать итүләрен таләп итте (аларны алдады), алар да аңа буйсындылар. Һичшиксез, алар фасикъ кешеләр иде»** («әз-Зухруф», 54).

### Мисырдан китү

Фиргавен һәм аның тарафдарлары, дөньялыктагы өстенлекләрен кулланып, Аллаһка иман китерүчеләргә төрлечә явызлык кыла. Үзләре күргән күп-күп могҗизаларга һәм үз башларына төшкән илаһи газап күренешләренә карамастан, алар һич баш бирмиләр, иманга килергә теләмиләр. Ниһаять, Муса галәйһис-сәләам аларга карата бәддога кылырга мәҗбүр була:

وَقَالَ مُوسَى رَبَّنَا إِنَّكَ آتَيْتَ فِرْعَوْنَ وَمَلَأَهُ زِينَةً وَأَمْوَالًا فِي الْحَيوةِ الدُّنْيَا رَبَّنَا لِيُضِلُّوا عَنْ سَبِيلِكَ رَبَّنَا اطْمِسْ عَلَى أَمْوَالِهِمْ وَاشْدُدْ عَلَى قُلُوبِهِمْ فَلَا يُؤْمِنُوا حَتَّى يَرَوُا الْعَذَابَ الْأَلِيمَ. قَالَ قَدْ أُجِيبَتْ دَعْوَتُكُمَا فَاسْتَقِيمَا وَلَا تَتَّبِعَآنِّ سَبِيلَ الَّذِينَ لَا يَعْلَمُونَ

**«Муса: “И, Раббыбыз! Фиргавенгә һәм аның олуг кешеләренә дөнья тормышында зиннәтләр һәм маллар бирдең. И, Раббыбыз! Нәтиҗәдә, алар Синең юлыңнан яздырдылар (Аларга ул нигъмәтләрне шуның өчен бирдеңме?). И, Раббыбыз! Аларның малларын һәлак ит! Тилмерткеч бер газапны күргәнчегә кадәр иман китермәсеннәр өчен, Син аларның йөрәкләрен бәйләп куй (иманга килсеннәр)”. (Аллаһ Муса белән Һарунга): “Икегезнең дә догасы кабул ителде. Сез туры юлны тотыгыз һәм белмәгән кешеләр юлына төшмәгез”, – диде»** («Йунус», 88–89).

Шуннан соң кыптыйларда тире авыруы башлана, өч көн корылык була. Һәр кыптый гаиләсенә аерым бертөрле бәла-каза килә. Фиргавен Бәни Исра-

ил кавеменең Мисырдан китүенә рөхсәт бирергә мәҗбүр хәлдә кала. Ләкин һәрвакыттагыча, куркыныч көннәр үткәч, янә сүзеннән кайтачагы шик уятмый.

Шунлыктан Муса галәйһис-сәләәм, Аллаһ кушканча эш йөртеп, төнлә Исраил угыллары белән бергә Сүвәйшкә таба юлга кузгала. Ул көннең таңында Фиргавен гаиләсендәге бөтен кызлар да ваба авыруы йоктырып үлә. Фиргавен болай да бик ачулы була, кызларының үлеме исә нәфрәтен тагын да арттыра: «Муса эше генә бу!» – дип җикеренә ул.

Фиргавеннең кызларын җирләү белән мәшгуль булуы Хәзрәти Мусага шактый вакыт отарга мөмкинлек тудыра. Чыннан да, Фиргавен Бәни Исраил угылларының китүен белеп алганда, аларны инде туктатып калырлык булмый… Аллаһ Тәгалә болай ди:

وَأَوْحَيْنَا إِلَى مُوسَى أَنْ أَسْرِ بِعِبَادِي إِنَّكُمْ مُتَّبَعُونَ

**«Без Мусага: ”Колларымны төнлә йөрт (юлга алып чык)! Һичшиксез, сезнең эзегезгә төшәчәкләр”, – дип вәхи иттек»** («әш-Шугара», 52).

وَلَقَدْ أَوْحَيْنَا إِلَى مُوسَى أَنْ أَسْرِ بِعِبَادِي فَاضْرِبْ لَهُمْ
طَرِيقًا فِي الْبَحْرِ يَبَسًا لَا تَخَافُ دَرَكًا وَلَا تَخْشَى

**«Без Мусага: “Колларымны төнлә йөрт (юлга алып чык), алар өчен диңгездә коры юл сал. Сине куып җитәр, дип курыкма (батып үлү турында борчылма)”, – дип вәхи иттек»** («Та-һә», 77).

Бу хәл турында белгәч, Фиргавен тәмам котырына:

فَأَرْسَلَ فِرْعَوْنُ فِي الْمَدَائِنِ حَاشِرِينَ. إِنَّ هَؤُلَاءِ لَشِرْذِمَةٌ قَلِيلُونَ.
وَإِنَّهُمْ لَنَا لَغَائِظُونَ. وَإِنَّا لَجَمِيعٌ حَاذِرُونَ

**«Фиргавен шәһәрләр буйлап (гаскәр) туплаучылар җибәрде.”Һичшиксез, алар бит аз санлы бер (таркау) көтү генә. Алар безне бик нык ачуландырдылар. Әмма һичшиксез без хәстәрен күрә торган (бердәм) кавембез” (дип әйтә һәм шулай дип әйттерә иде)»** («әш-Шугара», 53–56).

Ниһаять, Фиргавен, гаскәрен туплап, Муса галәйһис-сәләәм һәм Исраил угылларының эзләренә баса:

فَأَتْبَعُوهُمْ مُشْرِقِينَ. فَلَمَّا تَرَاءَ الْجَمْعَانِ قَالَ أَصْحَابُ مُوسَى
إِنَّا لَمُدْرَكُونَ. قَالَ كَلَّا إِنَّ مَعِيَ رَبِّي سَيَهْدِينِ

**«Алар (Фиргавен һәм кешеләре) кояш чыккан вакытта алар артыннан куып киттеләр. Ике төркем бер-берсен күргәч, Мусаның аркадашлары: “Һичшиксез, без куып җителгән кешеләрбез”, – диде. Ул (Муса): “Юк! Һичшиксез, Раббым минем белән бергә, Ул миңа юл күрсәтәчәк!” – диде»** («әш-Шугара», 60–62).

Муса галәйһис-сәләамнең алдында – Кызыл диңгез, артында исә Фиргавен гаскәре була.

**Кызыл диңгез – иминлек һәм һәлакәт диңгезе**

فَأَوْحَيْنَا إِلَى مُوسَى أَنِ اضْرِبْ بِعَصَاكَ الْبَحْرَ فَانْفَلَقَ فَكَانَ كُلُّ فِرْقٍ كَالطَّوْدِ الْعَظِيمِ

**«Без Мусага: “Таягың белән диңгезгә сук”, – дип вәхи иттек. (Сугуга ук) диңгез ярылды (унике юл ачылды) һәм һәрбер өлеш зур бер тау кебек булды»** («әш-Шугара», 63).

Бәни Исраил кавеме ике ягы тау кебек күтәрелгән сулар арасындагы юллардан бара башлый. Хәтта Исраил угыллары Хәзрәти Мусага: «И, Муса! Араларыбызда тәрәзәләр ачсаң иде, бер-беребезне күрик әле!» – дип тә мөрәҗәгать итә. Муса галәйһис-сәләам дога кыла. Дулкыннар арасында тәрәзәләр барлыкка килә. Юлдан барганда, иман ияләре бер-берсен күрә башлый.

Фиргавен бик масаючан, мин-минлекле бәндә, истидраж[128] иясе була. Ул гаскәренә борылып: «Диңгезгә карагыз әле! Мин үземнән алданрак киткән колларымны куып тота алсын өчен, бөеклегем аркасында диңгез әнә ничек ярылып, юлларга әйләнде!» Ягъни Фиргавен диңгезнең ярылып ачылуын Муса галәйһис-сәләам могҗиза итеп түгел, ә үзенең истидраҗы буларак күрерлек дәрәҗәдәге гафләт, ахмаклык һәм адашу эчендә була.

Аннары ул: «Аларның барысын да үтерәчәкмен! Диңгезгә керегез!» – дип гаскәрләренә әмер бирә. Ләкин шулчак куркып калып, бер мизгелгә икеләнеп тора, әллә баш тартырга микән, дип уйлый. Риваятькә күрә, шул вакытта Җәбраил галәйһис-сәләам ак ат өстендә алларына басып: «Әйдәгез, атлагыз!» – дип алга өнди.

Микаил галәйһис-сәләам исә Фиргавен армиясенең артына чыгып, арттагыларны: «Әйдәгез, артта калмагыз; атлагыз!» – дип куалый. Ахырда бөтен армия кузгалып китә.

Аллаһ Тәгалә бу хакта:

وَأَزْلَفْنَا ثَمَّ الْآخَرِينَ

128. Истидраж – Аллаһ Тәгаләнең гөнаһлы бәндәләргә, Аны инкяр итүчеләргә аларның хәсрәт-җәза диңгезенә тагын да ныграк батуларына китерә торган нигъмәтләр, мөмкинлекләр бирүе.

**«Башкаларны анда якынлаштырдык»**, – дип әйтә («әш-Шугара», 64).

Хәзрәти Муса һәм аның кавеме артыннан Фиргавен белән гаскәре дә диңгездә ачылган юлларга кереп китә. Фәкать илаһи каһәрнең бер чагылышы буларак, шул киң диңгез эчендә күмелеп калып, һәлак булалар.

وَأَنْجَيْنَا مُوسَى وَمَنْ مَعَهُ أَجْمَعِينَ. ثُمَّ أَغْرَقْنَا الْآخَرِينَ

**«Мусаны һәм янында булганнарны барысын бергә коткардык. Шуннан соң, башкаларны суга батырдык»** («әш-Шугара», 65–66).

فَانْتَقَمْنَا مِنْهُمْ فَأَغْرَقْنَاهُمْ فِي الْيَمِّ بِأَنَّهُمْ كَذَّبُوا بِآيَاتِنَا وَكَانُوا عَنْهَا غَافِلِينَ

**«Без исә алардан үч алдык, һәм аларны диңгездә батырдык, чөнки алар аятьләребезне ялган санадылар һәм алардан гафил кешеләр булдылар!»** («әл-Әгъраф», 136).

فَلَمَّا آسَفُونَا انْتَقَمْنَا مِنْهُمْ فَأَغْرَقْنَاهُمْ أَجْمَعِينَ. فَجَعَلْنَاهُمْ سَلَفًا وَمَثَلًا لِلآخِرِينَ

**«Алар Безне ачуландыргач, аларга җавап буларак җәза бирдек һәм аларның барысын да суга батырдык. Без аларны соңгылар өчен алдагылар (әүвәлгеләр) һәм бер гыйбрәт иттек»** («әз-Зухруф», 55–56).

إِنَّ فِي ذلِكَ لَآيَةً وَمَا كَانَ أَكْثَرُهُمْ مُؤْمِنِينَ

**«Һичшиксез, боларда бер билге бар. Әмма аларның күбесе иман китерүчеләр түгел иде»** («әш-Шугара», 67).

Аллаһның рәхмәте белән Бәни Исраил кешеләре барысы да исән-сау котыла. Бу мөхәррәм аеның 10 көне була. Шул вакыйга хөрмәтеннән бу көнне шөкер уразасы тоталар. Аллаһ Тәгалә Үзенең илаһи рәхмәте турында аяти кәримәдә болай искә ала:

وَإِذْ نَجَّيْنَاكُمْ مِنْ آلِ فِرْعَوْنَ يَسُومُونَكُمْ سُوءَ الْعَذَابِ يُذَبِّحُونَ
أَبْنَاءَكُمْ وَيَسْتَحْيُونَ نِسَاءَكُمْ وَفِي ذَلِكُمْ بَلَاءٌ مِنْ رَبِّكُمْ عَظِيمٌ.
وَإِذْ فَرَقْنَا بِكُمُ الْبَحْرَ فَأَنْجَيْنَاكُمْ وَأَغْرَقْنَا آلَ فِرْعَوْنَ وَأَنْتُمْ تَنْظُرُونَ

**«Без сезне, ир балаларыгызны чалып, (әшәкелек өчен) хатыннарыгызны гына исән калдырып, иң каты газапка дучар иткән Фиргавен токымыннан коткарган идек. Монда (яхшы күренгән нәрсәләрдә) сезнең өчен Раббыгыздан бик бөек бер сынау бар иде. Ул вакытта, диңгезне аерып, сезне коткардык, сез карап торганда, Фиргавен токымын суга батырдык»** («әл-Бәкара», 49–50).

**Фиргавеннең иманы кабул ителми**

وَجَاوَزْنَا بِبَنِي إِسْرَائِيلَ الْبَحْرَ فَأَتْبَعَهُمْ فِرْعَوْنُ وَجُنُودُهُ بَغْيًا وَعَدْوًا حَتَّى إِذَا أَدْرَكَهُ
الْغَرَقُ قَالَ آمَنْتُ أَنَّهُ لَا إِلَهَ إِلَّا الَّذِي آمَنَتْ بِهِ بَنُو إِسْرَائِيلَ وَأَنَا مِنَ الْمُسْلِمِينَ

**«Без Исраил улларын диңгез аша (исән-имин) үткәрдек, Фиргавен һәм аның гаскәрләре исә золым һәм дошманлык белән аларны куа китте. Ул (диңгездә) бата башлагач: "Һичшиксез, мин Исраил уллары ышанган Заттан башка һичбер илаһ булмаганына иман иттем. Мин дә – мөселманнарданмын!" – диде»** («Йунус», 90).

Кызыл диңгезнең төпсез чоңгылларында батыр алдыннан, мәҗбүр калгач, иман бөжрасына тотынып котылырга теләгән бичара Фиргавенгә Аллаһ Тәгалә болай дип белдерә:

آلْآنَ وَقَدْ عَصَيْتَ قَبْلُ وَكُنْتَ مِنَ الْمُفْسِدِينَ. فَالْيَوْمَ نُنَجِّيكَ بِبَدَنِكَ
لِتَكُونَ لِمَنْ خَلْفَكَ آيَةً وَإِنَّ كَثِيرًا مِنَ النَّاسِ عَنْ آيَاتِنَا لَغَافِلُونَ

**«"Хәзерме (иманга киләсең)? Моңарчы (гомереңбуе) каршы торган һәм бозыклык таратучылардан идең бит. (Ягъни бер бәла килгәндә, буйсындың, исән-сау калгач, кабат әүвәлгечә киреләнүеңне дәвам иттең! Хәзер исә мондый гамәлең белән инде синең иманга юнәлүең файдасыз. Әй, Фиргавен!) Бүген Без синнән соң киләчәк кешеләр өчен бер аять булсын дип, сине (җансыз бер) бәдәнең белән (коры җирдә югары бер урынга ташлап) коткарачакбыз". Әмма, һичшиксез, кешеләрнең күбесе Безнең аятьләребездән гафилләр»** («Йунус», 91–92).

Мөфәссир Зәмахшәри әлеге аяти кәримәне түбәндәгечә тәфсир кылган: «Сине диңгез ярындагы бер почмакка ыргытачакбыз. Җәсәдеңне тулы килеш, кимчелексез, бозылмаган хәлдә, ялангач, киемсез рәвештә, синнән гасырларча соңрак яшәячәк кешеләргә гыйбрәт итеп саклаячакбыз».

Соңгы елларда уздырылган тикшеренүләр нәтиҗәсендә Фиргавеннең җәсәде яр буенда йөзе белән сәҗдәгә капланган рәвештә табыла. Бу җәсәд хәзерге вакытта Бөекбритания музеенда саклана, халыкка ул бер гыйбрәт күренеше буларак күрсәтелә. Бу хикмәт – Җәнабел-Хакның Коръәни-Кәримдә белдереп куйган һәм кыяматкәчә сакланачак могҗизасы.

Фиргавен җәсәде йөзләрчә ел Кызыл диңгездә калуына карамастан, Аллаһ Тәгалә кодрәте белән, череми тора. Аяти кәримәдә дә белдерелгәнчә, аның гәүдәсе сакланып, бик күп гасырлардан соң ярга чыгарып ташлана. Өч мең елдан соң табылып, галәмнәргә гыйбрәт сыйфатында ул Англиядәге бер музейга куела.

Фиргавеннең Лондондагы Бөекбритания музеена (Англия) күргәзмәгә куелган җәсәде.

**Кызыл диңгезне кичкәч...**

Муса галәйһис-сәләәм Бәни Исраил кавемен Кәнан иленә таба алып бара. Юлда вакытта потларга һәм үгезгә табынучы бер кавемне очраталар. Кайберәүләр: «Йә, Муса! Безгә дә шундый берәр нәрсә ясап бир дә, шуңа табыныйк!» – дип әйтә. Хәзрәти Муса аларга: «Аллаһ сезне бер золымнан коткарды. Кыптыйлар улларыгызны үтерә, кызларыгызны хезмәтче итеп куллана иде. Шуңа карамастан сез, Аллаһка каршы баш күтәреп, ширеккә батасызмы?!» – дип нәсыйхәт укый.

Аллаһ Тәгалә бу вакыйганы болай дип сурәтли:

وَجَاوَزْنَا بِبَنِي إِسْرَآئِيلَ الْبَحْرَ فَأَتَوْا عَلَى قَوْمٍ يَعْكُفُونَ عَلَى أَصْنَامٍ لَهُمْ قَالُوا يَا
مُوسَى اجْعَلْ لَنَا إِلهًا كَمَا لَهُمْ آلِهَةٌ قَالَ إِنَّكُمْ قَوْمٌ تَجْهَلُونَ

**«Без Исраил улларын диңгез аша үткәрдек тә, алар (үзләренә генә хас) потларга табынган бер кавемгә тап булдылар һәм: “И, Муса! Аларның илаһлары кебек, безгә дә бер илаһ яса”, – диделәр». Ул (Муса) әйтте: «Һичшиксез, сез надан бер кавемсез»** («әл-Әгъраф», 138).

إِنَّ هَؤُلَاءِ مُتَبَّرٌ مَا هُمْ فِيهِ وَبَاطِلٌ مَا كَانُوا يَعْمَلُونَ. قَالَ أَغَيْرَ اللَّهِ أَبْغِيكُمْ إِلهًا
وَهُوَ فَضَّلَكُمْ عَلَى الْعَالَمِينَ. وَإِذْ أَنْجَيْنَاكُمْ مِنْ آلِ فِرْعَونَ يَسُومُونَكُمْ سُوءَ
الْعَذَابِ يُقَتِّلُونَ أَبْنَاءَكُمْ وَيَسْتَحْيُونَ نِسَاءَكُمْ وَفِي ذَلِكُمْ بَلَاءٌ مِنْ رَبِّكُمْ عَظِيمٌ

**«Боларның тоткан нәрсәләре (диннәре) һәлак ителәчәк һәм кылган нәрсәләре бушка китәчәк. (Муса) әйтте: “Сезне галәмнәрдән өстен кылган Аллаһтан башка берәүне сезгә илаһ буларак эзлимме әллә? Менә Без сезне Фиргавен гаиләсеннән коткардык. Алар сезгә иң каты газапны эзлиләр иде, ир балаларыгызны үтерәләр, хатыннарыгызны исә исән калдыралар иде. Монда (сезнең өчен) Раббыгыздан бер сынау бар иде”»** («әл-Әгъраф», 139–141).

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм 12000 кешелек ике гаскәр туплап, аны Мисырга җибәрә. Аның кавемендә бала-чагалар, авырулар һәм карт-коры гына кала. Гаскәрнең берсен – Юша ибне Нун галәйһис-сәләәм, икенчесен Калиб ибне Юхнә җитәкли. Хәрби сәфәрдән алар күп ганимәт белән кайта. Үзләре белән алып кайта алмаганнарын саталар. Хәзер инде кыптыйлар тәмам пыран-заран китерелә. Бу вакыйганы аяти кәримәләр түбәндәгечә аңлата:

فَأَخْرَجْنَاهُمْ مِنْ جَنَّاتٍ وَعُيُونٍ. وَكُنُوزٍ وَمَقَامٍ كَرِيمٍ

**«(Ахырда) шулай Без аларны (Фиргавен һәм аның кавемен), бакчалардан һәм чишмәләрдән чыгардык. Хәзинәләрдән һәм яхшы урыннардан да»** («әш-Шугара», 57–58).

وَأَوْرَثْنَا الْقَوْمَ الَّذِينَ كَانُوا يُسْتَضْعَفُونَ مَشَارِقَ الْأَرْضِ وَمَغَارِبَهَا الَّتِي بَارَكْنَا فِيهَا وَتَمَّتْ كَلِمَتُ رَبِّكَ الْحُسْنَى عَلَى بَنِي إِسْرَآئِيلَ بِمَا صَبَرُوا وَدَمَّرْنَا مَا كَانَ يَصْنَعُ فِرْعَوْنُ وَقَوْمُهُ وَمَا كَانُوا يَعْرِشُونَ

**«Зәгыйфь саналган (кимсетелгән) кавемне (яһүдиләрне) исә Без бәрәкәтле иткән җирнең көнчыгышларына һәм көнбатышларына мирасчы кылдык. Сабыр итүләре сәбәпле, Исраил улларына Раббыңның яхшы вәгъдәсе үтәлде. Без Фиргавен һәм аның кавеме торгызганнарны да, корганнарны (бакчаларны) да харап иттек»** («әл-Әгъраф», 137).

كَذلِكَ وَأَوْرَثْنَاهَا بَنِي إِسْرَائِيلَ

**«Менә шулай! Без аларга Исраил улларын мирасчы иттек»** («әш-Шугара», 59).

كَمْ تَرَكُوا مِنْ جَنَّاتٍ وَعُيُونٍ. وَزُرُوعٍ وَمَقَامٍ كَرِيمٍ. وَنَعْمَةٍ كَانُوا فِيهَا فَاكِهِينَ. كَذلِكَ وَأَوْرَثْنَاهَا قَوْمًا آخَرِينَ. فَمَا بَكَتْ عَلَيْهِمُ السَّمَاءُ وَالْأَرْضُ وَمَا كَانُوا مُنْظَرِينَ

**«Алар никадәр бакчалар һәм чишмәләр калдырдылар. Янә игеннәр һәм яхшы урыннар... Һәм алар эчләрендә хозурланган нигъмәтне. Менә шулай Без боларга башка кавемне мирасчы иттек. Алар өчен җир дә, күк тә еламады. Алар кичектерү бирелгән кешеләр дә булмадылар»** («әд-Духан», 25–29).

Илаһи каһәргә дучар булган авыр язмышларын һәм аларның тарих чүплегендә юкка чыгуларын Җәнабел-Хак түбәндәге аяти кәримәдә бик үтемле ачып бирә:

وَكَمْ أَهْلَكْنَا قَبْلَهُمْ مِنْ قَرْنٍ هَلْ تُحِسُّ مِنْهُمْ مِنْ أَحَدٍ أَوْ تَسْمَعُ لَهُمْ رِكْزًا

**«Без алардан әүвәл ничәмә-ничә буыннарны һәлак иткән идек! Син алардан берәрсен (әсәрен) таба аласыңмы? Яки аларның пышылдавын булса да ишетә аласыңмы?»** («Мәрьям», 98).

**Әриха җирлегендә Амалика кавеменә каршы сугыш белән сыналу һәм Тих чүле**

وَإِذْ قَالَ مُوسَى لِقَوْمِهِ يَا قَوْمِ اذْكُرُوا نِعْمَةَ اللَّهِ عَلَيْكُمْ إِذْ جَعَلَ فِيكُمْ أَنبِيَاءَ وَجَعَلَكُم مُّلُوكًا وَآتَاكُم مَّا لَمْ يُؤْتِ أَحَدًا مِّنَ الْعَالَمِينَ

**«Үз вакытында Муса кавеменә әйтте: “И, кавемем! Аллаһның сезгә (рәхмәте) булган нигъмәтен хәтерләгез, ул арагызда пәйгамбәрләр җибәрде, сезне хөкемдарлар итте (хөр бәндәләр итте) һәм галәмнәрнең берсенә дә бирмәгәннәрне сезгә бирде”»** («әл-Маидә», 20).

Әлеге аятьләр Хәзрәти Муса заманындагы Исраил угыллары белән бәйле. Шунлыктан аларның «дөньяда һичкемгә бирелмәгән нигъмәтләргә лаек булуы» да, «изге җирләрнең аларга ватан итеп язылып куелуы» да нәкъ әнә шул чорга гына карый. Югыйсә йөзләрчә аять һәм хәдис-шәриф Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килеп киткән һәм киләчәк бөтен кешелек өчен Аллаһның тиңсез рәхмәте һәм нигъмәте икәнлеген әйтеп тора. Изге җирләргә кем варис булырга тиешлеге турында Аллаһ Тәгаләнең ачыкламасы менә мондый:

وَلَقَدْ كَتَبْنَا فِي الزَّبُورِ مِنْ بَعْدِ الذِّكْرِ أَنَّ الْأَرْضَ يَرِثُهَا عِبَادِيَ الصَّالِحُونَ

**«Зикердән (Тәүраттан) соң Зәбүрдә дә яздык инде: “Ул җиргә Минем изге колларым мирасчы булачак”»** («әл-Әнбия», 105).

Бу аяти кәримәдә явызлыкның һәм залимнәрнең һәрвакыт хуҗа булмаячагы, игелекнең төп нигез, яманлыкның исә вакытлы икәнлеге; хакимиятнең иртәме-соңмы изгеләр кулына күчәчәгенең язмышка билгеләп куелганлыгы белдерелә. Бу да исламның дөнья тормышына карата глобаль карашын күрсәтә.

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм кавемен Кәнан төбәгенә алып килү өчен юлга чыга. Алар «Арзы Мәвгуд» (вәгъдә ителгән җирләр) дип аталган җиргә урнашырга җыена. Муса галәйһис-сәләәм һәр бүлектән бер вәкил сайлап ала. Юша ибне Нун һәм Калиб ибне Юхнә җитәкчелегендә андагы кавемгә разведка төркеме җибәрә. Алар амалика кавеме бик куәтле дигән нәтиҗәгә килә, ләкин үз кавемнәрендә бернинди дә курку хисе тумасын һәм кавемдәшләренең рухи халәте, кәефе бозылмасын өчен, амалика халкы турында сөйләмәскә сүз куешалар. Асылда Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм дә аларга әнә шулай эшләргә кирәклеген кисәтеп куя. Әмма Юша ибне Нун белән Калиб ибне Юхнәдән калганнар кавемнәренә чын вазгыятьне җиткерәләр. Исраил угыллары сугышка керүдән тыела:

يَا قَوْمِ ادْخُلُوا الْأَرْضَ الْمُقَدَّسَةَ الَّتِي كَتَبَ اللَّهُ لَكُمْ وَلَا تَرْتَدُّوا
عَلَى أَدْبَارِكُمْ فَتَنْقَلِبُوا خَاسِرِينَ. قَالُوا يَا مُوسَى إِنَّ فِيهَا قَوْمًا جَبَّارِينَ وَإِنَّا
لَنْ نَدْخُلَهَا حَتَّى يَخْرُجُوا مِنْهَا فَإِنْ يَخْرُجُوا مِنْهَا فَإِنَّا دَاخِلُونَ.

**«(Муса әйтте:) “И, кавемем! Аллаһ сезгә (ватан итеп) дип язган мөкатдәс туфракка керегез. Артыгызга борылмагыз, юкса соңыннан югалткан (хәсрәткә тарыган) кешеләргә кайтырсыз”. Алар: “И, Муса! Анда бит җәберләүче кешеләр бар. Алар аннан чыгып китмичә, без анда кермәячәкбез. Әгәр алар аннан чыксалар, без керәчәкбез”, – дигәннәр иде»** («әл-Маидә», 21–22).

قَالَ رَجُلَانِ مِنَ الَّذِينَ يَخَافُونَ أَنْعَمَ اللَّهُ عَلَيْهِمَا ادْخُلُوا عَلَيْهِمُ الْبَابَ
فَإِذَا دَخَلْتُمُوهُ فَإِنَّكُمْ غَالِبُونَ وَعَلَى اللَّهِ فَتَوَكَّلُوا إِنْ كُنْتُمْ مُؤْمِنِينَ.

**«Аллаһ үзләренә нигъмәт биргән, курыккан ике кеше: “Аларга капкадан керегез. Анда кергәч, сез җиңәчәксез. Әгәр ышанган кешеләр булсагыз, Аллаһка гына тәвәккәл итегез”, – дип әйткән иде»** («әл-Маидә», 23).

قَالُوا يَا مُوسَى إِنَّا لَنْ نَدْخُلَهَا أَبَدًا مَا دَامُوا فِيهَا فَاذْهَبْ أَنْتَ وَرَبُّكَ فَقَاتِلَا إِنَّا هَهُنَا قَاعِدُونَ

**«Алар (кяфер Исраил кавеме): “И, Муса! Һичшиксез, алар анда чакта, без анда беркайчан да кермәячәкбез. Син Раббың белән бар да, сез икәү сугышыгыз. Без исә монда утырып торырбыз”, – дигәннәр иде»** («әл-Маидә», 24).

Чөнки Фиргавен золымыннан котылганнан соң, ул чактагы газаплы көннәрне оныткан Исраил угыллары дөнья нигъмәтләренә тиенеп, рәхәтлеккә чыга. Аларның бу дөньялык өчен теләкләре көчәя, Хәзрәти Мусадан күк хәлвәсе һәм бүдәнә ите сорый башлыйлар. Бу нигъмәтләр аларга көн саен насыйп ителә. Боларга өстәп, Муса галәйһис-сәләәм таягы белән ташка суга һәм шул урыннан унике чишмә бәреп чыга.

Җәнабел-Хак болай ди:

وَظَلَّلْنَا عَلَيْكُمُ الْغَمَامَ وَأَنْزَلْنَا عَلَيْكُمُ الْمَنَّ وَالسَّلْوَى كُلُوا مِنْ
طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْ وَمَا ظَلَمُونَا وَلَكِنْ كَانُوا أَنْفُسَهُمْ يَظْلِمُونَ

**«Өстегезне болыт белән капладык һәм сезгә күк хәлвәсе һәм бүдәнәләр иңдердек. “Без биргән тәмле ризыклардан ашагыз!” (дидек). Әмма алар Безгә золым итмәделәр, үзләренә золым иттеләр»** («әл-Бәкара», 57).

وَإِذِ اسْتَسْقَى مُوسَى لِقَوْمِهِ فَقُلْنَا اضْرِبْ بِعَصَاكَ الْحَجَرَ فَانْفَجَرَتْ مِنْهُ اثْنَتَا عَشْرَةَ عَيْنًا
قَدْ عَلِمَ كُلُّ أُنَاسٍ مَشْرَبَهُمْ كُلُوا وَاشْرَبُوا مِنْ رِزْقِ اللَّهِ وَلَا تَعْثَوْا فِي الْأَرْضِ مُفْسِدِينَ

**«Бервакыт Муса (чүлдә) үзенең кавеме өчен су сораган иде, һәм Без аңа: “Таягың белән ташка ор!” – дидек. Аннан (таштан шундук) унике чишмә бәреп чыкты. Һәр кеше (төркем) үзенә кайдан эчәргә кирәклеген белә иде. (Аларга әйттек:) “Аллаһның ризыгыннан ашагыз, эчегез, әмма җирдә бозыклык кылып йөрмәгез!”»** («әл-Бәкара», 60).

وَقَطَّعْنَاهُمُ اثْنَتَيْ عَشْرَةَ أَسْبَاطًا أُمَمًا وَأَوْحَيْنَا إِلَى مُوسَى إِذِ اسْتَسْقَاهُ قَوْمُهُ أَنِ اضْرِبْ بِعَصَاكَ
الْحَجَرَ فَانْبَجَسَتْ مِنْهُ اثْنَتَا عَشْرَةَ عَيْنًا قَدْ عَلِمَ كُلُّ أُنَاسٍ مَشْرَبَهُمْ وَظَلَّلْنَا عَلَيْهِمُ الْغَمَامَ وَأَنْزَلْنَا
عَلَيْهِمُ الْمَنَّ وَالسَّلْوَى كُلُوا مِنْ طَيِّبَاتِ مَا رَزَقْنَاكُمْ وَمَا ظَلَمُونَا وَلَكِنْ كَانُوا أَنْفُسَهُمْ يَظْلِمُونَ

**«Без аларны (Исраил угылларын) кабиләләр итеп унике җәмәгатькә аердык. Кавеме су сораганда, Без Мусага: “Таягың белән ташка сук”, – дип вәхи иттек. Аннан унике чишмә бәреп чыкты, һәр кеше (кабилә) эчәргә тиешле урынны белде. Без болытны аларга күләгә иттек һәм аларга күк хәлвәсе белән бүдәнәләр (ите) иңдердек. (Аларга әйттек:) “Безнең сезне ризыкландырган нәрсәләрдән (пакьләрен) ашагыз”. Алар (кушканнарыбызны тыңламыйча) Безгә зарар китермәделәр, ләкин үз-үзләренә зарар китерделәр»** («әл-Әгъраф», 160).

يَا بَنِي إِسْرَائِيلَ قَدْ أَنْجَيْنَاكُمْ مِنْ عَدُوِّكُمْ وَوَاعَدْنَاكُمْ
جَانِبَ الطُّورِ الْأَيْمَنَ وَنَزَّلْنَا عَلَيْكُمُ الْمَنَّ وَالسَّلْوَى. كُلُوا مِنْ طَيِّبَاتِ مَا
رَزَقْنَاكُمْ وَلَا تَطْغَوْا فِيهِ فَيَحِلَّ عَلَيْكُمْ غَضَبِي وَمَنْ يَحْلِلْ عَلَيْهِ غَضَبِي
فَقَدْ هَوَى. وَإِنِّي لَغَفَّارٌ لِمَنْ تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ صَالِحًا ثُمَّ اهْتَدَى

**«И, Исраил уллары! Без сезне дошманыгыздан коткардык һәм сезнең белән Турның уң ягында (килүегезгә) вәгъдә иттек. Сезгә күк хәлвәсе белән бүдәнә (ите) иңдердек. Ризык итеп биргән нәрсәләребездән хәләл булганнарын ашагыз. (Бу мәсьәләдә) Бозыклык (һәм рәхмәтсезлек) кылмагыз, югыйсә сезгә Минем ачуым төшәр. Кемгә исә Минем ачуым төшсә, һичшиксез, ул һәлак булыр. Һичшиксез, Мин тәүбә иткән, иман китергән, изге гамәл кылган, шуннан соң (шул рәвешле) һидәяттә нык торганнарны, әлбәттә, гафу итүчемен»** («Та-һә», 80–82).

Исраил угыллары исә, һич теләкләре бетми, канәгатьләнә белми торган, шөкерсез һәм сабырсыз кавем булганга күрә, янә пәйгамбәрләренә авырлык

китереп, рәхмәтсез гамәлләрен дәвам иттерә. Түбәндәге аяти кәримә бу кавемнең рәхмәтсезлеген бик ачык сурәтләп күрсәтә:

وَإِذْ قُلْتُمْ يَا مُوسَى لَنْ نَصْبِرَ عَلَى طَعَامٍ وَاحِدٍ فَادْعُ لَنَا رَبَّكَ يُخْرِجْ لَنَا مِمَّا تُنْبِتُ الْأَرْضُ مِنْ بَقْلِهَا وَقِثَّائِهَا وَفُومِهَا وَعَدَسِهَا وَبَصَلِهَا قَالَ أَتَسْتَبْدِلُونَ الَّذِي هُوَ أَدْنَى بِالَّذِي هُوَ خَيْرٌ اهْبِطُوا مِصْرًا فَإِنَّ لَكُمْ مَا سَأَلْتُمْ وَضُرِبَتْ عَلَيْهِمُ الذِّلَّةُ وَالْمَسْكَنَةُ وَبَآؤُوا بِغَضَبٍ مِنَ اللهِ ذَلِكَ بِأَنَّهُمْ كَانُوا يَكْفُرُونَ بِآيَاتِ اللهِ وَيَقْتُلُونَ النَّبِيِّينَ بِغَيْرِ الْحَقِّ ذَلِكَ بِمَا عَصَواْ وَكَانُوا يَعْتَدُونَ

**«Бервакыт сез (бирелгән нигъмәтләре карата): “И, Муса! Бер үк төрле азыкка чыдый алмыйбыз. Безнең өчен Раббыңа дога кыл да, Ул безгә җир үстерә торган нәрсәләрдән – яшелчәсеннән: кыярыннан, бодаеннан, сарымсагыннан, ясмыгыннан һәм суганыннан чыгарсын”, – дигән идегез. Ул (Муса): “Әллә сез яхшырак нәрсәне түбәнрәк булган нәрсәгә алмаштырырга телисезме? (Алайса) бер шәһәргә керегез, һичшиксез, сез сораган нәрсәләр булыр”, – дигән иде. Шулай итеп, аларга (бу вакыйгадан соң) түбәнлек, юксыллык сугылды, алар үзләрен Аллаһның ачуына дучар иттеләр. Бу (кыенлыклар) аларга Аллаһны аятьләрен инкяр итүләре һәм нахакка пәйгамбәрләрне үтергәннәре өчен. Бу исә карышулары һәм чиктән чыкканнары өчен иде»** («әл-Бәкара», 61).

قَالَ رَبِّ إِنِّي لَا أَمْلِكُ إِلَّا نَفْسِي وَأَخِي فَافْرُقْ بَيْنَنَا وَبَيْنَ الْقَوْمِ الْفَاسِقِينَ. قَالَ فَإِنَّهَا مُحَرَّمَةٌ عَلَيْهِمْ أَرْبَعِينَ سَنَةً يَتِيهُونَ فِي الْأَرْضِ فَلَا تَأْسَ عَلَى الْقَوْمِ الْفَاسِقِينَ

**«(Ахырда) Ул (Муса): ”И, Раббым! Һичшиксез, мин үземә һәм кардәшемә генә хуҗа була алам. Син безнең белән гөнаһкярлар җәмәгате арасын аер“, – дигән иде». Ул (Аллаһ) әйтте: «Һичшиксез, ул (Изге җирләр) аларга кырык елга тыелды. Алар (бу вакыт эчендә) җирдә каңгырап йөриячәкләр. Син ул гөнаһлы кавем өчен хәсрәт чикмә»** («әл-Маидә», 25–26).

وَلَقَدْ أَخَذَ اللَّهُ مِيثَاقَ بَنِي إِسْرَآئِيلَ وَبَعَثْنَا مِنْهُمُ اثْنَيْ عَشَرَ نَقِيبًا وَقَالَ اللهُ إِنِّي مَعَكُمْ لَئِنْ أَقَمْتُمُ الصَّلوةَ وَآتَيْتُمُ الزَّكوةَ وَآمَنْتُمْ بِرُسُلِي وَعَزَّرْتُمُوهُمْ وَأَقْرَضْتُمُ اللَّهَ قَرْضًا حَسَنًا لَأُكَفِّرَنَّ عَنْكُمْ سَيِّئَاتِكُمْ وَلَأُدْخِلَنَّكُمْ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ فَمَنْ كَفَرَ بَعْدَ ذَلِكَ مِنْكُمْ فَقَدْ ضَلَّ سَوَاءَ السَّبِيلِ

**«Аллаһ Исраил улларыннан сүз алган иде. Һәм Без алар арасыннан (гарант буларак) унике юлбашчы җибәргән идек. Аллаһ (аларга) әйт-**

**кән иде: “Мин сезнең белән. Әгәр намазны укысагыз, зәкятне бирсәгез, рәсүлләргә ышансагыз, аларны олыласагыз һәм игелекле нәрсәләрне Аллаһка бурычка бирсәгез (мохтаҗларга Аллаһ ризалыгы өчен процентсыз бурычка бирсәгез), яман эшләрегезне сездән сөртермен һәм сезне асларыннан елгалар аккан җәннәтләргә кертермен. Моннан соң исә кайсыгыз инкяр итсә, ул туры юлдан язган (булыр)”»** («әл-Маидә», 12).

Ләкин Бәни Исраил кавеме Аллаһның үзләренә биргән нигъмәтләренә шөкер итми һәм үлүл-газыйм пәйгамбәрләренең өченчесе булган Хәзрәти Мусага карата кирелекләрен, башбаштаклыкларын дәвам иттерә. Хәтта Пәйгамбәрләренә: «Син Раббың белән бергә яуга бар: сугыш һәм җиң! Аннары без дә синең артыңнан килербез!» – дип әйтерлек дәрәҗәдә хөрмәтсез, әдәпсез кыланалар.

Шунлыктан Җәнабел-Хак аларны кырык ел буе бик җайсыз, кысан Тих чүлендә яшәргә хөкем итә. Бу җирдән чыгарга маташканда, әйләнеп йөрийөри бары шул ук урынга килеп чыгалар. Бу җирдә яңа бер нәсел үсеп җитә...

Ниһаять, бу иманлы һәм ныклы нәсел белән андагы диктатор, кысрыклаучы кавемне җиңеп, Арзы Мевгудка аяк басалар. Хәзер инде алар Иордан елгасының көнчыгыш ярындагы җирләрне кулга төшереп, Арзы Мевгудка урнашу мөмкинлеге ала. Шулай итеп, Муса галәйһис-сәләәм вәгъдә иткән җиргә киләләр.

**Тәүрат иңдерелү**

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм Исраил угыллары белән бергә Мисырдан китеп, дошманнан котылгач, өммәтенә Аллаһ катыннан бер китап иңдереләчәген хәбәр итә. Муса галәйһис-сәләәм Һарун галәйһис-сәләәмне үз урынына вәкил итеп калдыра: «Син боларның ялгыш гамәлләрен төзәт! Мин Аллаһның әмере белән Сина тавына китәм. Анда утыз көн ураза тотачакмын. Аллаһтан иңәчәк яңа Китап белән кайтачакмын!» – ди. Ләкин рәхмәтсез кавеме: «Яныңда безнең арадан шаһитлар булуын телибез, и Муса!» – дип, аның ялгыз гына китүенә каршы чыга. Шулай итеп, җитмеш кешене сайлап алып, барысы бергә Сина тавына юл тота.

Муса галәйһис-сәләәм вәгъдә ителгән Китап турында Җәнабел-Хакка ялвара. Хак Тәгалә аңа утыз көн ураза тотарга куша. Бу зөлкагъдә аеның утыз көне була. Соңыннан зөлхиҗҗә аеның беренче ун көне белән бергә бу ураза кырык көнгә җыела. Хәзрәти Мусага Китап бирелеп, аңа кавемен туры юлга ирештерү вазифасы йөкләнә.

Аллаһ Тәгалә:

وَوَاعَدْنَا مُوسَى ثَلَاثِينَ لَيْلَةً وَأَتْمَمْنَاهَا بِعَشْرٍ فَتَمَّ مِيقَاتُ رَبِّهِ أَرْبَعِينَ لَيْلَةً

**«Без Муса белән (Миңа гыйбадәт кылу өчен) утыз төн турында килештек һәм аларны (тагын) ун белән җиткердек, шулай итеп Раббың билгеләгән вакыт кырык төн булды...»** – дип хәбәр итә («әл-Әгъраф», 142).

Хәзрәти Муса бу вазифа таләп иткән камиллеккә ирештерәчәк ураза тоту, тыелып тору, гыйбадәт, дога, игътибар туплау, күңелне пакьләү һәм фикерләү өчен кырык көнгә Сина тавына чакырыла. Муса галәйһис-сәләам шушы кырык төн эчендә Раббы белән күрешүгә әзерләнергә тиеш була. Күкләрнең тынлыгына чуму, җирләрнең мәшәкатьләреннән ерагаю, ахырда исә чиксез киңлекләрдә бөек Яралтучыга барып җитеп, күңел диңгезенә чуму өчен, Муса галәйһис-сәләам Сина тавында башка кешеләрдән аерым яши, чөнки рухын пакьләп яктыртыр һәм аңа йомшаклык, нәфислек бирер өчен, әнә шундый ихтыяҗы була.

Моннан аңлашылганча, тәүге утыз көн ураза башка гыйбадәтләр белән бергә рухи төзәтү, пакьләнү, аз белән канәгатьләнү булып тора; ахыргы ун көндә Тәүрат иңдерелә һәм Аллаһ белән сөйләшү чынга аша, ягъни Муса галәйһис-сәләам шушы кырык көнлек вакыт эчендә Аллаһ Тәгалә белән аралаша алырлык югары рухи дәрәҗәгә күтәрелә.

Аяти кәримәдә без күнеккәнчә кырык көн урынына кырык төн, дип әйтелүе, айлар төн белән башланганга күрә, көн белән түгел, төннәр белән саналуы аркасында. Димәк ки, бу хисапка көннәр дә керә. Шулай ук, көндезге як белән чагыштырганда, төннең үз үзенчәлекләре дә бар. Бик күп илаһи күренешләр төннәрен чынга аша. Коръәни-Кәримнең ләүхелмәхфуздән төнлә иңдерелүе, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мигъраҗ сәфәренә төнлә чыгуы кебекләр...

Муса галәйһис-сәләамнең Сина тавында кырык төн калуына төрле хәбәрләр, төрле ишарәтләр салынган. Иман әһелләре олуг илаһи күренеш таңын күрә алсын өчен, төн кебек караңгы, газаплы, авыр сәгатьләрнең узуын көтәргә тиеш. Илаһи фазыйләт һәм бәрәкәт, гомумән алганда, төннәрен насыйп ителә. Бөтен уңышлы иртәләр авыр төннәрнең сәхәрләренә ияреп килер.

Муса галәйһис-сәләам бу сынавында кырык көннең, әйтерсең, тәүге утыз көне бер тулы төнне, аннан соңгы ун көн исә шул төннең сәхәрен тәшкил итә. Бу сәхәрнең таң сызыгы беленү сәгатьләрен хәтерләткән соңгы вакытларында Хәзрәти Муса галәйһис-сәләам, Аллаһ Тәгалә белән сөйләшү бәхетенә ирешеп, бик күп илаһи күренешләрнең шаһитына әйләнә.

Муса галәйһис-сәләам Сина тавында бертуктаусыз утыз көн ураза тота һәм бу вакытта ачыкмый да, кибекми дә!.. Ләкин Хозыр белән очрашыр өчен сәфәргә чыгарга кушылгач кына, ярты көн дә узмый, сабырлыгы төкәнә һәм бик ачыга. Муса галәйһис-сәләам дустына: «Ризыкларыбызны чыгар, ашап алыйк!» – ди. Чөнки аның Хозыр янына баруы бер сынау белән бәйле була. Бу сынауга исә артык баглылык хисе өстәлә. Аллаһ яралткан бер мәхлук белән очрашу юлында Муса галәйһис-сәләам ярты көндә ачыга. Ләкин Сина тавын-

да торган вакыты һәм Аллаһ янына сәфәр кылуы исә Хак Тәгалә белән кавышу сәфәрен һәм Аның белән әңгәмәне күздә тота, шуңа күрә Синада чакта ул ашау-эчүне оныта, Аллаһтан башка һичнәрсәгә игътибар бирми.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү белән сөйләшү бәхетенә ирешкәнлектән, Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәмне «Кәлимуллаһ» дип атыйлар. Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм Җәнабел-Хак белән без күзаллаган тел кебек әгъза, корал ярдәмендә түгел, вакытка һәм тарафка бәйсез рәвештә, Аның мәңгелек «Кәлам» сыйфаты аша сөйләшә. Аллаһның сыйфатларыннан һичкайсы мәхлукларга хас сыйфатларга охшамый. Ул – Галим, ягъни һәрнәрсәне белә, ләкин бу хәбәрдарлык безгә хас белү кебек түгел. Ул сөйләшә, тик Аның сөйләшүе безнеке белән чагыштырылмас!.. Без тел кебек бер матди чара һәм авазлар ярдәмендә сөйләшәбез. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү мондый сыйфатлардан азат. Авазлар мәхлук булып тора, ягъни аларны Аллаһ яралткан. Аллаһның кәламе исә мәхлук түгел, авазы да, коралы да юк. Муса галәйһис-сәләәм Аллаһ Җәллә Җәләлүһү белән сөйләшкәндә, янындагы 70 кеше һәм Җәбраил галәйһис-сәләәм бу әңгәмәне тоя да, аңлый да алмыйлар...

Кәлимуллаһ Муса ибне Гыймран галәйһис-сәләәм рухи дөньядагы берничә күренешкә шаһит була. Алар пәйгамбәр теләге белән булган дигән сүз түгел. Риваятькә күрә, сыйфаты-мәгънәсе безгә билгесез дүрт мең йөз егерме сүз һәм тагын ундүрт сүз Муса галәйһис-сәләәмгә турыдан-туры тәкъдим ителә. Һәр җибәрелгән сүз Хәзрәти Мусага бик көчле тәэсир ясый һәм аны тетрәндерә. Аның гәүдәсе һәм холкы бу сүзләрне кабул итүе сәбәпле, бик нык үзгәреш кичерә. Әлеге элемтә белән бәйле рәвештә аяти кәримәдә:

وَكَلَّمَ اللّٰهُ مُوسَى تَكْلِيمًا

**«…Аллаһ Муса белән (һичшиксез) сөйләште»**, – дип әйтелә («ән-Ниса», 164).

Муса галәйһис-сәләәмнең күңелендәге ачу-нәфрәт кебек хисләрне басыр һәм аны юатыр өчен, илаһи нигъмәтләр белән аның җаны бераз гына булса да тынычлык тапсын өчен, Аллаһ Тәгалә меңләгән үгет-нәсыйхәт җибәрә!.. Чөнки Муса галәйһис-сәләәм давыллар һәм өермәләр белән тулы гомер кичерә, материалист карашлы азгын кавем – Бәни Исраил халкына шәригать хөкемнәрен кертү өчен җибәрелгән бер пәйгамбәр була...

### Кырык санының хикмәте

Кырык саны рухи өлгергәнлек күзлегеннән бик әһәмиятле булып тора:

а) Хәзрәти Адәм ясалачак балчыкның үзләнүе кырык көн дәвам итә. Риваятьтә: *«Аллаһ Адәмгә чимал булачак туфракны кырык көн кодрәтле кулы белән изә»*, – дип тапшырыла (Табәри, «Тәфсир», III, 306). Бу көннәрнең һәрберсе мәгънәсе безгә билгесез булган вакыт берәмлеген тәшкил итә.

б) Һәр кеше ана карынында 40 көн яралгы, 40 көн ябышкан балчык (сөлек) һәм 40 көн чәйнәлгән ит кисәге рәвешендә була, аннары аңа җан өрелә. «Сахихайн»да[129] бу мәсьәләгә кагылышлы мондый хәдис-шәриф бар:

Ибне Мәсгуд радыйаллаһу ганһе тапшыра:

«Садыйк (тугры) һәм Масдук (тугрылыгы расланган) зат булган Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *“Дөреслектә сездән һәрберегез, анагыз карынында яралтылганда, кырык көн тамчы шәкелендә, соңыннан шулай ук кырык көн буена сөлек шәкелендә, соңыннан шулкадәр үк вакыт ит кисәге рәвешендә булыр. Соңыннан Аллаһ бер фәрештәне 4 төрле нәрсә белән җибәрер. Бу фәрештә аның ризыгын, әҗәлен, гамәлен һәм җәннәтме әллә җәһәннәм әһелеме булачагын язып куяр, аннары җан өрелер...”* – дип әйткән» (Бохари, «Кадәр»», 1; «Бәдгуль-халк», 6; Мөслим, «Кадәр», 1/2643).

в) Пәйгамбәрләрнең Хак Тәгалә сүзен ишетүләре ягыннан караганда да, кырык көн бик зур әһәмияткә ия булган кебек, әүлияларның йөрәкләреннән хикмәт чишмәләре бәреп чыксын өчен дә мөһимлеге бәхәссез. Бу: *«Кырык таңда ихласлык белән Раббысына юнәлгән затның йөрәгеннән теленә хикмәт чишмәләре агар!»* –дигән хәдис-шәриф белән раслана (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 137/8361).

Тасаувыфта рухи алгарыш өчен кырык көн дәвамында кулланылган, «чилә» яки «әрбагыйн» дип атап йөртелгән йоланың башлангычын менә шушы хәдис-шәриф һәм Муса галәйһис-сәләамнең Сина тавында яшәгән кырык көне турындагы аяти кәримәләр тәшкил итә.

Җисми асылның руханияткә бәйләнеше дә, аннан аерылуы да 40 саны белән нисбәтле, чөнки Аллаһның кануны әнә шундый.

Дүрт санының һәм дүрт кабатлыларының әһәмиятенә дин галимнәре дә игътибар иткән. Мәсәлән, галәмнең нигезен дүрт элемент формалаштыра: су, һава, җир һәм ут. Аллаһ гареше дүртпочмаклы булып, аны сигез мәләк күтәреп йөри. Муса галәйһис-сәләамгә кырык көн (төн) ураза тотарга һәм аз белән канәгатьләнеп яшәргә кушыла, әнә шуннан соң гына аңа Раббы белән сөйләшү мөмкинлеге бирелә…

### Муса галәйһис-сәләамнең Аллаһны күрергә теләве

Җәнабел-Хак белән сөйләшкәндә, Муса галәйһис-сәләамнең күз каршындагы пәрдәләр күтәрелә. Вакытка һәм урынга бәйсез рәвештә, ул Аллаһның бөек гарешен ап-ачык күрә ала. Ләүхелмәхфузны язып торган каләмнең кыштырдауларын ишетә. Янында Җәбраил галәйһис-сәләам һәм 70 кеше торса да, алар һичнәрсә ишетми. Чөнки Муса галәйһис-сәләам бик югары урынга һәм дәрәҗәгә күтәрелгән була.

129. «Сахихайн» – бөтен ислам галимнәре тарафыннан танылган алты хәдис китабыннан Бохари һәм Мөслим җыентыкларының уртак атамасы.

Ниһаять, Муса галәйһис-сәләәм бу аралашудан шулкадәр ләззәт ала ки, шатлык-сөенече бик арта. Анда бөтенләй башка халәт барлыкка килә һәм ул Җәнабел-Хакны күрергә тели. Бу теләген гаять үҗәтләнеп белдерә. Аллаһ Тәгалә исә: «لَنْ تَرَانِي» **«Син Мине күрә алмыйсың!»** – дип җавап бирә.

Муса галәйһис-сәләәм үтенечен тагын кабатлагач, Җәнабел-Хак: «Әнә теге тауга кара! Ул тау шул урынында басып тора алса, син дә Мине күрә алырсың!» – дип аңлата (Бу Мәдйән илендәге Зөбәйр дип аталган бик зур тау була).

Бер риваятьтә әйтелгәнчә, Җәнабел-Хак Муса галәйһис-сәләәмгә җитмеш хиҗаб (пәрдә) аркылы бер дирһәм кадәр генә нур күрсәтә. Нур тауга чагыла һәм бу тау җимерелә. Муса галәйһис-сәләәм бу кодрәт һәм бөеклекнең көченә, зурлыгына түзә алмый һәм, куркып, һушын югалта.[130] Аяти кәримәдә бу вакыйга түбәндәгечә тасвирлана:

وَلَمَّا جَاءَ مُوسَى لِمِيقَاتِنَا وَكَلَّمَهُ رَبُّهُ قَالَ رَبِّ أَرِنِي أَنْظُرْ إِلَيْكَ قَالَ لَنْ تَرِينِي وَلَكِنِ انْظُرْ إِلَى الْجَبَلِ فَإِنِ اسْتَقَرَّ مَكَانَهُ فَسَوْفَ تَرِينِي فَلَمَّا تَجَلَّى رَبُّهُ لِلْجَبَلِ جَعَلَهُ دَكًّا وَخَرَّ مُوسَى صَعِقًا فَلَمَّا أَفَاقَ قَالَ سُبْحَانَكَ تُبْتُ إِلَيْكَ وَأَنَا أَوَّلُ الْمُؤْمِنِينَ

**«Муса билгеләнгән вакытка (Турга) килгәч, һәм Раббысы аның белән сөйләшкәч, ул: “И, Раббым! Күрсәт миңа да (үзеңне), карыйм сиңа!” – диде. Ул (Раббы): “Син Мине күрә алмассың, ләкин шул тауга кара. Әгәр ул урынында тора алса, син дә Мине күрә алырсың”, – диде. Раббысы тау ачылгач, аны кисәк-кисәк итте. Муса һуштан язып егылды. Аңына килгәч исә: “Син (бөтен кимчелекләрдән) пакь! Сиңа тәүбә итәм. Мин бит иман китерүчеләрнең беренчесемен”, – диде»** («әл-Әгъраф», 143).

Тасаувыф әһелләре бу мәсьәләдә ишари мәгънәләрне дә ачыклыйлар:

Муса галәйһис-сәләәм бәндәчел аң белән чиксез мәгънә диңгезенең хикмәтен күрергә тели. Ләкин аның үтенеченә каршы бирелгән җавап ул теләгәнчә булмый. Чөнки аның аң-зиһене күңел күзе белән бер, ә күңеле, үзе уйлавынча, бердәнбер була. Шунлыктан Раббысын күрергә тели дә. Фәкать Муса галәйһис-сәләәм илаһи күренеш мизгелендә һушын югалта. Шулчакта аңа аңлаешлы тел белән: «И, Муса! Мондый югары уңыш, бәхет синең өчен түгел. Ул синнән соң киләчәк ятимнеке», – дип хәбәр ителә.

Бу мөрәҗәгатьне раслап, Хәзрәти Муса болай ди: «Йә, Раббы! Сине тәсбих әйтәм һәм һәртөрле кимчелектән пакьлегеңне таныйм. Бары Сиңа гына хас булганча сөекле итеп кылган һәм үзенә иң югары дәрәҗәләрне биргән

130. Моңа охшаш риваятьләрне өйрәнер өчен, боларны карагыз: Хаким, «Мүстәдрәк», II, 630, хәдис №4102–4105; Әлмалылы, IV, 2276; Әбү Нугайм, «Хилья», V, 55.

Хәзрәти Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм генә Синең янына ирешә алыр. Минем өчен булмаган бернәрсәне сораганга күрә, Сиңа тәүбә итәм. Мин шаһитлык дәрәҗәләренең иң югарысы Хәзрәти Мөхәммәд Мостафаныкы икәнлегенә иман китерүчеләрнең иң беренчесемен!»

Риваятькә күрә, Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм Сина тавыннан кайткан-да, аның йөзендә һаман да Аллаһ Тәгаләнең нуры чагыла. Шуңа күрә өч көн буе йөзен каплап йөри.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Муса галәйһис-сәләәм ул хозур кылу урынында булганнан соң, аңа кем караса да, үлеп китә. Шуннан соң Муса галәйһис-сәләәм йөзен бер япма белән каплый. Кешеләр белән берара әнә шул рәвештә аралашып йөри»*, – дип әйткән (Суюти, «әд-Дүррүл-Мәнсур фит-Тәфсири бил-Мәэсур», III том, 116 б.).

Урвә ибне Рувәйм болай дип тапшыра: «Раббы белән сөйләшкәннән соң, Муса галәйһис-сәләәм хатынына якын килә алмый һәм йөзен каплап йөри, чөнки аңа караган һәркем бакыйлыкка күчә. Хатыны аңа: “Инде кырык ел сиңа гына карап яшим, мине дә бер караш белән сөендерсәң иде!” – дип белдерә. Моңа җавап итеп, Муса галәйһис-сәләәм йөзен каплаган пәрдәне күтәрә. Аның йөзендәге кояштай нур хатынын тәмам чорнап ала, аның күзләре камаша. Хатын шундук йөзен куллары белән каплап, Аллаһка сәҗдәгә каплана» (Суюти, «әд-Дүррүл-Мәнсур фит-Тәфсири бил-Мәэсур», III том, 116 б.).

Вәһб ибне Мүнәббиһ болай дип тапшыра: «Муса галәйһис-сәләәмнең Аллаһ белән һәр әңгәмәсеннән соң өч көн буе йөзендә гаҗәеп нур күренгән» (Суюти, «әд-Дүррүл-Мәнсур фит-Тәфсири бил-Мәэсур», III том, 116 б.).

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм Сина тавына Аллаһ тарафыннан кылынган искиткеч манзара каршында аңын югалтып егыла һәм аннары өч көн йөзен каплап йөрерлек дәрәҗәдә яктылык чәчүгә лаек була. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез дә Мигъраҗ вакытында Сидрәтүл-Мүнтәхадан да арырак күктә, Коръән сүзләре белән әйткәндә, **«ике ук арасы кадәр ераклыкта, хәтта аннан да якынрак»**[131] дип бәяләнгән кавышу-күрешү мизгелендә, Җәнабел-Хак белән әңгәмә кору һәм аны күрү нигъмәтенә ирешә. Шул дәрәҗә күтәрелүгә карамастан, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмдә ник Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәмдәге кебек бер тәэсир күренмәгәнлеге мәсьәләсен ислам галимнәре түбәндәгечә аңлата:

Бу хәл-вакыйгаларны кичергәндә, Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм «тәлвин» иясе була. Пәйгамбәр Әфәндебез галәйһис-саләтү вәс-сәләәм исә «тәмкин»[132] иясе булуга ирешә. Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм

131. Карагыз: «ән-Нәҗем» сүрәсе, 9 нчы аять.

132. Тәлвин – тәмкин дәрәҗәсенә ирешү юлында кичкән төрле хәлләр, бер халәттән икенчесенә күчеш. Тәмкин – туры юлдан, һидәят юлыннан барып, рухи ныгу, тирәнәю; Хак Тәгаләгә ирешү халәтендә күңелдән карар кылып, аның билгеле бер рухи хозурлыкка әйләнүе.

Әфәндебез һәрдаим Аллаһны күреп тору халәтендә була. Мигъраҗда бер илаһи хозурлык башка дәрәҗәдәге хозурлыкка гына, бер илаһи шаһитлык төшенчәсе бөтенләй башка шаһитлык төшенчәсенә генә әйләндерелә. Әлеге үзенчәлек хәдис-шәрифләрдә дә очрый:

*«Мин сездән берегез кебек түгел: Раббым янында кунам, Раббым мине ашатыр-эчертер»* (Гали әл-Муттакый, «Кәнзүл-Уммал», 3/32, 42).

*«Минем Җәнабел-Хак белән шундый мизгелләрем була ки, аны якын фәрештәләр дә, һичбер пәйгамбәр дә аңлый-тоя алмас»* (Мүнави, «Фәйзүл-Кадир», IV, 8).[133] Ислам галимнәре Җәнабел-Хакның: **«(Йә, Муса!) Син мине күрә алмыйсың!»** рәвешендәге мөрәҗәгатенә дә ишари тәфсир кыла: «Йә Муса! Син булганда, ягъни син Миндә эреп югалганчы, Мин синең өчен яшерен. Шаять Син Миндә эрерсең, Мин Сиңа ачык булырмын!»

Ягъни күктә Кояш булганда, йолдызлар ничек күренми торса, диңгезгә тоташкан елга анда ничек югалып китсә, күзгә сөрмә итеп тартканда, таш ташлыктан алгандагы сыйфатларын ничек бетергән булса, бер бодай бөртеге тәнгә ризык булып кергәннән соң, үзенең бодайлыгын ничек тәмам югалтыр булса, Аллаһта фани булучының туфрактан ясалган гәүдәсе дә шулай рухи яктан юкка чыгар, ул үз-үзенә чит кешегә әйләнер.

Мәүләна Җәләлетдин Руми, нәфес тәэсиреннән котылу өчен, үлем килгәнен бик зарыгып көтә. Бу мизгелне ул «шәби арус» (туй кичәсе) дип атый. Халлаҗ әл-Мансур да рухи һушсызлык халәтендә: «Дуслар! Үтерегез мине! Чөнки мине үлем коткарачак!» – дип әйткән.

Мондый хәлне тасаувыфта «вәхдәт әл-вөҗүд» яки «вәхдәт әл-шөһүд» дип атыйлар. Ләкин бу, асылда, вакытлы халәт. Һәм әлеге рухи халәтнең чын асылын аны кичергәннәр генә аңлый ала.

Җәнабел-Хак белән Аның мәңгелек кәлам сыйфатының чагылышы ярдәмендә сөйләшү нәтиҗәсендә, Муса галәйһис-сәләәмдә бик тәмле һәм рәхәт теләк-омтылыш барлыкка килә. Ул шушы халәтендә Җәнабел-Хакка: «Раббым! Сине күримче!» – дип үҗәтләнеп мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә исә илаһи бер күренеш тәэсирендә тау җимерелә, ә Муса галәйһис-сәләәм, аңын югалтып, егыла. Һушына килгәч, тәүбә итеп, ярлыкау сорый. Муса галәйһис-сәләәм, Аллаһның сүзләрен ишеткәч, гүя үзенең бу дөньяда икәнен оныта, үзен ахирәткә, җәннәт һәм Аллаһның рәхмәтенә ирешкән, дип уйлый.

Риваятькә күрә, илаһи нурның бер кисәкчеген кабул итүдән килеп чыккан чагылыш тәэсирендә тау ярылып, тәмам вакланып бетә. Һәр кисәге берәр җиргә тарала. Тау гүя он кебек вакланып, елгаларга агып тарала. Бу таудан бер өлеш эләккән сулар татлылана, бу суларны эчкән авырулар шифа таба.

133. Карагыз: «Әл-Макдиси. Серләрнең ачылышы һәм хәзинәләрнең ачкычлары», 58–59 б.

Аллаһ Тәгалә сүзләрдәге бөек чагылыш булган Коръәни-Кәрим турында аяти кәримәдә болай ди:

لَوْ أَنْزَلْنَا هَذَا الْقُرْآنَ عَلَى جَبَلٍ لَرَأَيْتَهُ خَاشِعًا مُتَصَدِّعًا مِنْ خَشْيَةِ اللهِ وَتِلْكَ الْأَمْثَالُ نَضْرِبُهَا لِلنَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَتَفَكَّرُونَ

**«Әгәр дә Без бу Коръәнне бер тауга иңдергән булсак, син аны Аллаһтан куркудан буйсынган хәлдә яргаланганын күрер идең. Бу мисалларны Без кешеләргә фикерләсеннәр, дип китерәбез»** («әл-Хәшер», 21).

Шул сәбәпле биек таулары белән җир һәм киң офыклары белән күкләр илаһи әманәтне үз җаваплылыкларына алудан читенсенә. Бу хакыйкатьне Җәнабел-Хак түбәндәгечә хәбәр итә:

إِنَّا عَرَضْنَا الْأَمَانَةَ عَلَى السَّمَوَاتِ وَالْأَرْضِ وَالْجِبَالِ فَأَبَيْنَ أَنْ يَحْمِلْنَهَا وَأَشْفَقْنَ مِنْهَا وَحَمَلَهَا الْإِنْسَانُ إِنَّهُ كَانَ ظَلُومًا جَهُولًا

**«Без ул әманәтне күкләргә, җиргә һәм тауларга тәкъдим иттек, ләкин алар аны өсләренә алудан баш тарттылар һәм аңардан (җаваплылыктан) курыктылар. Кеше исә аны өстенә алды. Һичшиксез, ул залим һәм надан булды»** («әл-Әхзәб», 72).

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләамнең Аллаһ белән әңгәмәсеннән соң, Тәүрат иңә башлый. Ул җиде яки ун сәхифә рәвешендә иңдерелә. Барлыгы кырык җүз була. Тәүрат иңдерелгәндә, Җәбраил галәйһис-сәләам белән бергә һәр хәреф өчен бер фәрештәгә йөкләмә бирелә. Бу фәрештәләр Сина тавы түбәсендә Тәүратны Хәзрәти Мусага тәкъдим итә.

### Сина тавындагы сөйләшү

Муса галәйһис-сәләамнең Аллаһ Тәгалә белән әңгәмәсен Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез болай бәян кыла:

*«Хәзрәти Муса галәйһис-сәләам үзенә хас дип санаган алты үзенчәлек һәм дә үзе бер дә яратмаган җиденче сыйфаты турында Раббысына сораулар бирә:*

*«Йә, Раббы! Кайсы колың иң тәкъвасы?»*
*«Һәрдаим зикер кылучы һәм һич онытмаучы».*
*«Кайсы колың иң күп һидәяткә ирешүче?»*
*«Һидәяткә, туры юлга иярүчеләр (Китап һәм сөннәт кысаларында яшәүчеләр».*
*«Кайсы колың хөкем чыгаруда иң гаделе?»*
*«Кешеләргә үзен хөкем иткәндәй хөкем чыгаручы».*

*«Кайсы колың иң галиме?»*

*«Гыйлемнән һич туймаганы (һәм гыйлемен гыйрфанга әйләндергән, ягъни үз тормышы белән дәгъват кылучы)».*

*«Кайсы колың иң хөрмәтлесе?»*

*«Көчле хәлендә гафу итә белүче».*

*«Кайсы колың иң бае?»*

*«Үзенә бирелгәнгә риза булучы (һәм байлыгын Аллаһ юлында тотучы)».*

*«Кайсы колың иң фәкыйре?»*

*«Комсызы, ягъни үзен кимчелекле тоеп, үзенә бирелгәнне аз санап, артыгын теләүче (канәгатьләнә белмәүче)»* (Гали әл-Муттакый, «Кәнзүл-Уммал», XV, 899/43549).

**Алтын бозау**

Муса галәйһис-сәләәм белән бергә Кызыл диңгез аша кичкәннән соң, Исраил угыллары сыер башы рәвешендәге потларга табынучы бер кабиләне очрата. Хәзрәти Мусага кавеме: «Син дә безгә шундый бер тәңре яса да шуңа гыйбадәт кылыйк!» – дип мөрәҗәгать итә.

Муса галәйһис-сәләәм үгет-нәсыйхәт белән бу гамәлнең бик зур ширек булуын аңлата. Кавемдәгеләр үтенечләренә үкенеп, тәүбә итәләр. Ләкин Муса галәйһис-сәләәм, Һарун галәйһис-сәләәмне үз урынына башлык итеп калдырып, Сина тавына киткәч, алардан үзенең имансызлыгын яшереп йөргән Самири исемле бер рәхмәтсез яһүди Хәзрәти Мусаның юклыгыннан файдаланып калырга ашыга. Ул халыктан алтын җыя да бер бозау ясый. Аннары: «Бу – Мусаның тәңресе! Тик Муса үзенең тәңресен онытты!» – дип, халыкны бозауга табынырга котырта.

Самири бик оста иҗат кешесе була. Бозауны шундый оста итеп ясый ки, эченә җил кергәндә, ул тере хайван кебек мөгрәгән тавыш чыгара. Бу – бозаудагы махсус тишекләр ярдәмендә эшләнә. Җилнең көченә бәйле рәвештә, курайга охшаган тавышлар да чыга. Шуннан соң Самири: «Карагыз, тәңрегез сезнең белән сөйләшә!» – дип әйтә. Шул рәвешле Самири, бу бозауның тәңре булу турындагы фикерне сеңдереп, Исраил угылларының бер өлешен хак диннән ерагайта. Һарун галәйһис-сәләәм аларны төрлечә кисәтергә тырыша, тик аны тыңламыйлар.

Бу хәл аяти кәримәләрдә түбәндәгечә бәян ителә:

وَلَقَدْ قَالَ لَهُمْ هَارُونُ مِنْ قَبْلُ يَا قَوْمِ إِنَّمَا فُتِنْتُمْ بِهِ وَإِنَّ رَبَّكُمُ الرَّحْمَنُ فَاتَّبِعُونِي وَأَطِيعُوا أَمْرِي

**«Хәлбуки, элек Һарун аларга: “И, кавемем! Сез бит аның сәбәпле фәкать бер фетнәгә дучар булдыгыз. Һичшиксез, сезнең Раббыгыз Рахман бит. Миңа ияргез һәм әмеремә итагать итегез!” – дигән иде»** («Та-һә», 90).

قَالُوا لَنْ نَبْرَحَ عَلَيْهِ عَاكِفِينَ حَتَّى يَرْجِعَ إِلَيْنَا مُوسَى

**«Алар: “Муса безгә кайтканчы, без аңа табынудан туктамаячакбыз”, – диделәр»** («Та-һә», 91).

قَالَ فَإِنَّا قَدْ فَتَنَّا قَوْمَكَ مِنْ بَعْدِكَ وَأَضَلَّهُمُ السَّامِرِيُّ

**«(Ул чакта Синада булган Хәзрәти Мусага Аллаһ Тәгалә) әйтте: “Без синең артыңнан ук кавемеңне (Һарун белән калган Исраил угылларын) фетнәгә төшердек һәм Самири аларны юлдан яздырды”»** («Та-һә», 85).

وَاتَّخَذَ قَوْمُ مُوسَى مِنْ بَعْدِهِ مِنْ حُلِيِّهِمْ عِجْلًا جَسَدًا لَهُ خُوَارٌ أَلَمْ يَرَوْا أَنَّهُ لَا يُكَلِّمُهُمْ وَلَا يَهْدِيهِمْ سَبِيلًا اِتَّخَذُوهُ وَكَانُوا ظَالِمِينَ

**«(Синага киткән) Мусаның кавеме аның артыннан бизәнү әйберләреннән мөгри торган бер бозау сынын (ясап, һәйкәл итеп) алдылар. Алар аның үзләре белән сөйләшмәгәнен һәм аларны туры юлга илтмәгәнен күрмәделәрме әллә? (Гаҗизлегенә карамастан) алар аны (тәңре итеп) ясадылар һәм залим кешеләр булдылар»** («әл-Әгъраф», 148).

وَلَمَّا رَجَعَ مُوسَى إِلَى قَوْمِهِ غَضْبَانَ أَسِفًا قَالَ بِئْسَمَا خَلَفْتُمُونِي مِنْ بَعْدِيَ أَعَجِلْتُمْ أَمْرَ رَبِّكُمْ وَأَلْقَى الْأَلْوَاحَ وَأَخَذَ بِرَأْسِ أَخِيهِ يَجُرُّهُ إِلَيْهِ قَالَ ابْنَ أُمَّ إِنَّ الْقَوْمَ اسْتَضْعَفُونِي وَكَادُوا يَقْتُلُونَنِي فَلَا تُشْمِتْ بِيَ الْأَعْدَاءَ وَلَا تَجْعَلْنِي مَعَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ

**«Муса кызып һәм кайгырып, кавеменә кайткач: “Минем арттан кылган нәрсәгез нинди яман! Әллә сез Раббыгызның әмерен (көтеп тормыйча) ашыктырдыгызмы?” – диде. Ул ләүхәләрне ташлады һәм, абыйсының (Һарунның) башын тотып, аны үзенә тарта башлады. Ул (туганы) әйтте: “И, анамның улы! Һичшиксез, бу кавем мине көчсез калдырды һәм мине үтермәкче булды. Син мине хурлавың белән дошманнарны сөендермә һәм мине залим кешеләр җөмләсеннән санама”»** («әл-Әгъраф», 150).

قَالَ يَا هَارُونُ مَا مَنَعَكَ إِذْ رَأَيْتَهُمْ ضَلُّوا. أَلَّا تَتَّبِعَنِ أَفَعَصَيْتَ أَمْرِي. قَالَ يَا ابْنَ أُمَّ لَا تَأْخُذْ بِلِحْيَتِي وَلَا بِرَأْسِي إِنِّي خَشِيتُ أَنْ تَقُولَ فَرَّقْتَ بَيْنَ بَنِي إِسْرَائِيلَ وَلَمْ تَرْقُبْ قَوْلِي

**«(Муса) әйтте: “И, Һарун! Аларның юлдан язганнарын күргәч, комачаулаудан сине нәрсә тотып калды? Миңа иярмәдең? Әллә син әмеремә каршы чыктыңмы?” (Һарун) әйтте: “И, анамның улы! Сакалымны да,**

**башымны да тотма! Мин синең, Исраил улларын бүлгәләдең һәм минем сүземне үтәмәдең, дип әйтәчәгеңнән курыктым”»** («Та-һә», 92–94).

Хәзрәти Муса белән Хәзрәти Һарун бертуганнар була. Килеп туган вазгыятьтә Һарун галәйһис-сәләәмнең «анамның улы» дип дәшүендә сәбәп – Муса галәйһис-сәләәмнең мәрхәмәтенә өмет итүендә. Чөнки ана кеше атадан да, туганыңнан да шәфкатьлерәк. Өстәвенә, аларның әниләре Аллаһка иман китергән, улларының сөю-хөрмәтен яулаган игелекле ана була.

قَالَ رَبِّ اغْفِرْ لِي وَلِأَخِي وَأَدْخِلْنَا فِي رَحْمَتِكَ وَأَنْتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ

**«Ул (Муса) әйтте: “И, Раббым! Мине һәм кардәшемне гафу ит һәм безне рәхмәтеңә керт. Син бит мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе”»** («әл-Әгъраф», 151).

فَرَجَعَ مُوسَى إِلَى قَوْمِهِ غَضْبَانَ أَسِفًا قَالَ يَا قَوْمِ أَلَمْ يَعِدْكُمْ رَبُّكُمْ وَعْدًا حَسَنًا أَفَطَالَ عَلَيْكُمُ الْعَهْدُ أَمْ أَرَدْتُمْ أَنْ يَحِلَّ عَلَيْكُمْ غَضَبٌ مِنْ رَبِّكُمْ فَأَخْلَفْتُمْ مَوْعِدِي.

**«(Соңыннан) Муса бик ярсу һәм хәсрәтле хәлдә кавеменә кайтты һәм: “И, кавемем! Раббыгыз бик яхшы бер вәгъдә бирмәдеме? Сезгә ул вакыт озын булып тоелдымы, әллә үзегезгә Раббыгызның ачуы төшүен теләп, сүземне боздыгызмы?” – диде»** («Та-һә», 86).

قَالُوا مَا أَخْلَفْنَا مَوْعِدَكَ بِمَلْكِنَا وَلَكِنَّا حُمِّلْنَا أَوْزَارًا مِنْ زِينَةِ الْقَوْمِ فَقَذَفْنَاهَا فَكَذَلِكَ أَلْقَى السَّامِرِيُّ. فَأَخْرَجَ لَهُمْ عِجْلًا جَسَدًا لَهُ خُوَارٌ فَقَالُوا هَذَا إِلَهُكُمْ وَإِلَهُ مُوسَى فَنَسِيَ

**«Алар: “(Йә, Муса!) Без синең сүзеңне үз-үзебезгә белә торып бозмадык. Ләкин без ул җәмгыятенең (мисырлыларның) бизәнгеч әйберләреннән бик күп авыр йөк алган идек, аларны ташладык. Самири (дә шулай ук) ташлады”, – диделәр (Самиринең тәкъдиме белән бизәнгечләрне эретү һәм бозау ясау өчен утка ташлыйлар). Ул, бозауның мөгрәве булган бер җәсәдән аларга чыгарды (мөгри белгән бозау сыны ясады) да алар: “Бу – сезнең илаһыгыз һәм Мусаның илаһы, әмма ул онытты”, – диделәр»** («Та-һә», 87–88).

Хәзрәти Муса аларның бу әшәке гамәлләренә тәүбә итүләрен теләи. Тәүбә шартының исә бик үкенү һәм үлемнән гыйбарәт икәнен белдерә. Кавемдәшләре исә: «Сабыр итәрбез!» – диләр һәм илаһи хөкем чыгарылуын көтәләр.

وَإِذْ قَالَ مُوسَى لِقَوْمِهِ يَا قَوْمِ إِنَّكُمْ ظَلَمْتُمْ أَنْفُسَكُمْ بِاتِّخَاذِكُمُ الْعِجْلَ فَتُوبُوا إِلَى بَارِئِكُمْ فَاقْتُلُوا أَنْفُسَكُمْ ذَلِكُمْ خَيْرٌ لَكُمْ عِنْدَ بَارِئِكُمْ فَتَابَ عَلَيْكُمْ إِنَّهُ هُوَ التَّوَّابُ الرَّحِيمُ

**«Ул вакытта Муса кавеменә: “И, кавемем! Һичшиксез, сез, ул бозауны (тәңре итеп) алып, үз-үзләрегезгә золым иттегез. Яралтучыгызга тәүбә итегез дә үз-үзләрегезне (нәфесләрегезне) үтерегез. Бу – Яралтучыгыз хозурында сезнең өчен иң хәерлесе”, – дигән иде, һәм Ул (Аллаһ) сезнең тәүбәгезне кабул иткән иде, чөнки, хактыр ки: Ул – тәүбәләрне Кабул итүче, Рәхимле»** («әл-Бәкара», 54).

Җәзалап үтерергә тиешле кешеләр үтерелергә тиешле затларның баш очында кылыч тоткан килеш көтә башлый. Потка табынган һәр кешегә аның муенын чабып өзәчәк башка берәү билгеләнә. Хәтта болар арасында бер-берсенә туган тиешлеләре дә була:

وَلَمَّا سُقِطَ فِي أَيْدِيهِمْ وَرَأَوْا أَنَّهُمْ قَدْ ضَلُّوا قَالُوا لَئِنْ
لَمْ يَرْحَمْنَا رَبُّنَا وَيَغْفِرْ لَنَا لَنَكُونَنَّ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«Куллары өстенә төшкәч (үкенгәч) һәм үзләренең юлдан язганлыкларын күргәч: “Әгәр Раббыбыз безне кызганмаса һәм безне ярлыкамаса, без зарар күрүчеләрдән булачакбыз”, – диделәр»** («әл-Әгъраф», 149).

Хәзрәти Муса һәм Хәзрәти Һарун, шәфкатьлелекләре аркасында, елый-елый дога кыла. Шуннан соң аять иңдерелә һәм аларның кавемдәшләренең тәүбәләре кабул ителә:

وَالَّذِينَ عَمِلُوا السَّيِّئَاتِ ثُمَّ تَابُوا مِنْ بَعْدِهَا وَآمَنُوا إِنَّ رَبَّكَ مِنْ بَعْدِهَا لَغَفُورٌ رَحِيمٌ

**«Әмма начар нәрсәләр эшләгән һәм соңыннан тәүбәгә килгән һәм иман китергәннәр! Һичшиксез, синең Раббың – Гафу итүче, Рәхимле»** («әл-Әгъраф», 153).

Һәм Аллаһ Тәгалә:

ثُمَّ عَفَوْنَا عَنْكُمْ مِنْ بَعْدِ ذَلِكَ لَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ

**«Шуннан соң, бәлки, (акылга килеп) шөкер итәрсез, дип, Без сезне гафу иттек»**, – дип хәбәр итә («әл-Бәкара», 52).

Шуннан соң Муса галәйһис-сәләәм Самиригә таба борыла:

قَالَ فَمَا خَطْبُكَ يَا سَامِرِيُّ. قَالَ بَصُرْتُ بِمَا لَمْ يَبْصُرُوا بِهِ فَقَبَضْتُ
قَبْضَةً مِنْ أَثَرِ الرَّسُولِ فَنَبَذْتُهَا وَكَذلِكَ سَوَّلَتْ لِي نَفْسِي

**«Ул: “Син нәрсә диярсең, Самири?” – диде. Ул: “Мин алар белмәгән бернәрсәне белдем (күрдем)! Шуңа күрә ул илченең эзеннән бер уч (туфрак) алып, аны (эрегән җәүһәрләр эченә) ташладым. Нәфесем болай миңа бизәп күрсәтте”, – диде»** («Та-һә», 95–96).

Мөфәссирләр фикеренчә, башкалар күрмичә, үзенең генә күргәнлеге, аның эзеннән бер уч туфрак алганлыгы турында Самири сөйләгән ул илче Хәзрәти Муса янына килгән Җәбраил була. Самири, аның аты баскан җирләрнең яшелләнгәнен күрә дә, бу эзнең туфрагыннан бер уч алып, аны алтыннар эретә торган утка ташлый.

قَالَ فَاذْهَبْ فَإِنَّ لَكَ فِي الْحَيوةِ أَنْ تَقُولَ لاَ مِسَاسَ وَإِنَّ لَكَ مَوْعِدًا لَنْ تُخْلَفَهُ
وَانْظُرْ إِلَى إِلهِكَ الَّذِي ظَلْتَ عَلَيْهِ عَاكِفًا لَنُحَرِّقَنَّهُ ثُمَّ لَنَنْسِفَنَّهُ فِي الْيَمِّ نَسْفًا

**«(Муса) әйтте: “Инде кит! Һичшиксез, гомереңдә сиңа, “кагылмагыз”, дип әйтергә туры киләчәк. Синең өчен бер вәгъдә ителгән урын бар ки, син аннан кача алмаячаксың. Син юнәлгән илаһыңа кара! Һичшиксез, аны яндырачакбыз, шуннан соң диңгезгә очырып бетерәчәкбез”»** («Та-һә», 97).

Риваятькә күрә, Муса галәйһис-сәләәмнең аяти кәримәдәге бәддогасыннан соң Самири, чыннан да, бик авыр һәм йогышлы чир эләктерә һәм гомер буе кешеләрдән ерак йөрергә мәҗбүр була.

إِنَّ الَّذِينَ اتَّخَذُوا الْعِجْلَ سَيَنَالُهُمْ غَضَبٌ مِنْ رَبِّهِمْ وَذِلَّةٌ
فِي الْحَيوةِ الدُّنْيَا وَكَذلِكَ نَجْزِي الْمُفْتَرِينَ

**«Һичшиксез, бозауны (тәңре итеп) алган кешеләргә Раббыларының ачуы һәм дөнья тормышында хурлык киләчәк. Без ялганчыларны әнә шулай җәзага дучар итәбез»** («әл-Әгъраф», 152).

وَلَمَّا سَكَتَ عَنْ مُوسَى الْغَضَبُ أَخَذَ الْأَلْوَاحَ وَفِي نُسْخَتِهَا هُدًى وَرَحْمَةٌ لِلَّذِينَ هُمْ لِرَبِّهِمْ يَرْهَبُونَ

**«Мусаның ярсуы басылгач, ул ләүхәләрне алды. Анда язылганнарда Раббыларыннан курыккан кешеләр өчен бер һидәят һәм бер рәхмәт (хәбәре) бар»** («әл-Әгъраф», 154).

Муса галәйһис-сәләәмгә Аллаһ Тәгалә, бозауга табынганнарына үкенгән Исраил угылларыннан вәкил сыйфатында җитмеш кеше сайлап алып, Аның

хозурына китерергә һәм бергәләп тәүбә итәргә куша. Хәзрәти Муса, илаһи әмердә таләп ителгәнчә, җитмеш кеше белән Сина тавына юл тота. Ләкин рәхмәтсез кавем Аллаһны күрү теләген белдерә. Шуннан соң анда куркыныч җир тетрәү килеп чыга һәм алар, һушларын югалтып, егыла. Ахырда Хәзрәти Муса Аллаһка ялвара һәм бу афәт туктатыла.

Аяти кәримәләрдә болай диелә:

وَإِذْ قُلْتُمْ يَا مُوسَى لَنْ نُؤْمِنَ لَكَ حَتَّى نَرَى اللَّهَ جَهْرَةً فَأَخَذَتْكُمُ الصَّاعِقَةُ وَأَنْتُمْ تَنْظُرُونَ. ثُمَّ بَعَثْنَاكُمْ مِنْ بَعْدِ مَوْتِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ

**«Сез (бервакыт): “И, Муса, Аллаһны ачыктан-ачык күрмичә, без сиңа ышанмабыз”, – дигән идегез. Сезне шунда ук, үзегез карап торган хәлдә, яшен тоткан иде. Шуннан соң үлемегез артыннан сезне терелттек, бәлки сез шөкер итәрсез?!»** («әл-Бәкара», 55–56).

وَاخْتَارَ مُوسَى قَوْمَهُ سَبْعِينَ رَجُلًا لِمِيقَاتِنَا فَلَمَّا أَخَذَتْهُمُ الرَّجْفَةُ قَالَ رَبِّ لَوْ شِئْتَ أَهْلَكْتَهُمْ مِنْ قَبْلُ وَإِيَّايَ أَتُهْلِكُنَا بِمَا فَعَلَ السُّفَهَاءُ مِنَّا إِنْ هِيَ إِلَّا فِتْنَتُكَ تُضِلُّ بِهَا مَنْ تَشَاءُ وَتَهْدِي مَنْ تَشَاءُ أَنْتَ وَلِيُّنَا فَاغْفِرْ لَنَا وَارْحَمْنَا وَأَنْتَ خَيْرُ الْغَافِرِينَ

**«Муса Без билгеләгән вакыт өчен кавеменнән җитмеш кеше сайлады. Җир тетрәү аларны тоткач, (Муса) әйтте: “И, Раббым! Әгәр теләгән булсаң, элегрәк үк боларны да, мине дә һәлак итәр идең. Арабыздагы ахмаклар кылган бернәрсә (гөнаһ) аркасында безне һәлак итәчәксеңме? Бу – Синең сынавың, теләгәнеңне моның белән юлдан яздырырсың, теләгәнеңне исә һидәяткә ирештерерсең. Син – безнең Яклаучыбыз. Безне ярлыка һәм безне рәхмәтле кыл. Син бит ярлыкаучыларның иң яхшысы!”»** («әл-Әгъраф», 155).

Муса галәйһис-сәләәм догасын түбәндәге сүзләр белән дип дәвам итә:

وَاكْتُبْ لَنَا فِي هذِهِ الدُّنْيَا حَسَنَةً وَفِي الْآخِرَةِ إِنَّا هُدْنَا إِلَيْكَ

**«Безнең өчен бу дөньяда да, Ахирәттә дә хәерле нәрсә яз. Һичшиксез, без Сиңа кайттык (Синең һидәятеңә юнәлдек)»** («әл-Әгъраф», 156).

**«...(Аллаһ Тәгалә җавабында) әйтте: “Мин газабымны теләгәнемә җибәрәм, рәхмәтем исә һәрнәрсәне каплап алган. Мин аны тәкъвалык иялӓренә, зәкят бирүчеләргә һәм аятьләребезгә инанган кешеләр өчен язабыз. Ул кешеләр яннарындагы Тәүрат һәм Инҗилдә язылган Рәсүлгә, өмми Нәбигә (Хәзрәти Мөхәммәдкә) ияраләр. Ул аларны яхшылыкка өнди, начарлыклардан тыя, пакь нәрсәләрне аларга хәләл итә, кабахәт**

**нәрсәләрне исә аларга харам кыла, авыр йөкләрен һәм моңарчы өсләрендә булган богауларны алардан ала. Аңа иман китергән кешеләр аны олылар лар, аңа ярдәм итәрләр һәм аның белән бергә иңдерелгән нурга ияреләр. Әнә шулар – (асыл моратка барып) уңышка ирешүчеләр"»** («әл-Әгъраф», 156–157).

Сәхабәләрдән Катадә ибне Ногман радыйаллаһу ганһе тапшырганча, Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм болай дигән:

«Йә, Раббы! Мин ләүхәләрдә кешеләр арасыннан чыгарылган, яхшылыкка өндәгән, начарлыклардан тыйган иң хәерле бер өммәт турында сүз барганын күрәм. Аллаһым, аларны минем өммәтем кыл!» Аллаһ Тәгалә: «Алар – Әхмәднең өммәте», – ди.

Муса галәйһис-сәләәм: «Раббым! Ләүхәләрдә дөньяга килүдә соңгы, җәннәткә керүдә беренче булган бер өммәт турында сүз барганын күрәм. Аларны минем өммәтем кыл!» – дип ялвара. Аллаһ Тәгалә: «Алар – Әхмәднең өммәте», – ди.

Муса галәйһис-сәләәм: «Йә, Раббы! Тагын ләүхәләрдә бер өммәт турында сөйләнә. Аларның Инҗилләре (китаплары) күңелләрендә йөрер, шуннан аны яттан укырлар. Ә алардан әүвәлге өммәтләр китапларын карап укыганнар, китаплары югалгач исә, аннан бернәрсә хәтерли алмаганнар. Һичшиксез, Син бу өммәткә элеграк һичбер өммәткә бирелмәгән ятлау һәм яхшы хәтердә калдыру сәләте биргәнсең. Аллаһым! Аларны минем өммәтем кыл!» – дип сорый. Аллаһ Тәгалә: «Алар – Әхмәднең өммәте», – ди.

Хәзрәти Муса: «Раббым! Анда әүвәлге китапларга да, соңгы китапка дә иман китергән, һәртөрле адашу, азгынлык белән көрәшкән бер өммәт искә алына. Аны минем өммәтем кыл!» – ди. Аллаһ Тәгалә: «Ул – Әхмәднең өммәте», – дип белдерә.

Муса галәйһис-сәләәм: «Раббым! Анда шундый бер өммәт телгә алына, алардан берсе ниндидер игелек кылырга ниятләп, бу гамәлне эшли алмаса да, аңа 10нан 700гә санда әҗер-савап бирелә. Аларны минем өммәтем кыл!» – дип сорый. Аллаһ Тәгалә: «Алар – Әхмәднең өммәте», – ди.

Риваятьтә тапшырылганча, шуннан соң Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм, кулындагы ләүхәләрне бер читкә куеп: «Аллаһым! Мине дә Мөхәммәд өммәтеннән кылсаң иде!» – дип ялвара (Ибне Кәсир, «Тәфсир», II, 259).

Аллаһ Тәгаләгә хәмед-сәнәләребез булсын, без бернинди түләүсез-нисез Мөхәммәд өммәте булып дөньяга килдек. Шуңа күрә никадәр генә шөкер итсәк тә, аздыр. Ләкин һәрнәрсәнең кыйммәте, хакы булган кебек, бу нигъмәтнең дә хакы бар. Димәк, без Мөхәммәд өммәте булуның җаваплылыгын тиешенчә аңларга һәм Аның хозурында хәерле өммәт булып яшәргә тиешбез, кыямәт көнендә Аның тирәсендә урын алып, Аның бөек шәфәгатенә лаек булыйк.

Исраил угыллары күпмедер вакыт тынычлыкта гомер кичерә, аннары янә азгынлыкка төшәләр. Тәүрат хөкемнәренең читенлегенә, аларны үтәп яшәүнең авырлыгына зарланып, тәүбә иткәндә биргән сүзләре турында онывталар. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү исә Сина тавын, бер могҗиза итеп, кинәт калкытып, алар өстенә күтәреп куя. Исраил угыллары, бик куркуга төшеп, сәҗдәгә каплана. Тау менә-менә җимерелер, дип көтә башлыйлар:

وَإِذْ أَخَذْنَا مِيثَاقَكُمْ وَرَفَعْنَا فَوْقَكُمُ الطُّورَ خُذُوا مَا آتَيْنَاكُمْ بِقُوَّةٍ وَاذْكُرُوا مَا فِيهِ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ. ثُمَّ تَوَلَّيْتُمْ مِنْ بَعْدِ ذٰلِكَ فَلَوْلَا فَضْلُ اللّٰهِ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَتُهُ لَكُنْتُمْ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«Без Турны сезнең өстегезгә күтәрдек һәм көчле вәгъдәгезне алдык. "Без сезгә биргәнне нык тотыгыз һәм анда булганны истә тотыгыз, бәлки, тәкъвалык ияләре булырсыз". Шуннан соң сез йөз чөергән идегез. Әгәр сезгә Аллаһның фазылы һәм рәхмәте булмаса, әлбәттә, сез зарар күрүчеләрдән булыр идегез»** («әл-Бәкара», 63–64).

Ләкин Исраил угыллары төзәлергә уйламыйча, элеккечә яшәүләрен дәвам итә. Бөтенләй азганнары илаһи газапка тотыла:

وَلَقَدْ عَلِمْتُمُ الَّذِينَ اعْتَدَوا مِنْكُمْ فِي السَّبْتِ فَقُلْنَا لَهُمْ كُونُوا قِرَدَةً خَاسِئِينَ. فَجَعَلْنَاهَا نَكَالًا لِمَا بَيْنَ يَدَيْهَا وَمَا خَلْفَهَا وَمَوْعِظَةً لِلْمُتَّقِينَ

**«Һичшиксез, арагыздагы шимбәдә чикләрдән чыкканнарны сез яхшы белә идегез. Без аларга: "Җирәнгеч маймыллар булыгыз!" – дип әйткән идек. Шул рәвешчә Без моны (маймылланган бәндәләрне) алардан алда булган буынга да, алардан соң булганнарга да гыйбрәт, тәкъвалык ияләренә нәсыйхәт иттек»** («әл-Бәкара», 65–66).

Аллаһ Тәгалә Бәни Исраил кешеләреннән күрәләтә торып гөнаһка чумганнарын маймылга әйләндерә, соңыннан бөтенләй һәлак итә. Бу җәза кешеләрнең асыл чыгышы маймылдан, дигән фикер белән һич бәйле түгел. Өстәвенә, маймылга әйләндерелгән гөнаһ ияләренең нәселе дә калмый.

Аллаһ Тәгалә болай ди:

فَبِمَا نَقْضِهِمْ مِيثَاقَهُمْ لَعَنَّاهُمْ وَجَعَلْنَا قُلُوبَهُمْ قَاسِيَةً يُحَرِّفُونَ الْكَلِمَ عَنْ مَوَاضِعِهِ وَنَسُوا حَظًّا مِمَّا ذُكِّرُوا بِهِ وَلَا تَزَالُ تَطَّلِعُ عَلَى خَائِنَةٍ مِنْهُمْ إِلَّا قَلِيلًا مِنْهُمْ فَاعْفُ عَنْهُمْ وَاصْفَحْ إِنَّ اللّٰهَ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ

**«Вәгъдәләрен бозганнары өчен, Без аларны ләгънәтләдек һәм калебләрен катырдык. Алар сүзләренең урыннарын алмаштырып үзгәртәләр**

**иде (Изге китапларыннан тайпылалар иде). Алар вәгазь ителгәннең бер өлешен оныттылар. Араларыннан бик азларыннан тыш, син алардан мәйданга киләчәк бер хыянәткә тап булачаксың. Янә аларны кичер һәм күз йом. Чөнки, һичшиксез, Аллаһ яхшы гамәл кылучыларны сөя»** («әл-Маидә», 13).

Тәүрат бердәнбер нөсхәдә була. Аны һичкем тулысынча яттан белми. Исраил угыллары, Вавилон кавеменә әсирлеккә эләккәч, әлеге бердәнбер Тәүрат нөсхәсе югала. Күп еллардан соң Исраил угыллары әсирлектән котылгач, хәтердә калган кайбер бүлекләре яңадан языла. Бүген халыкка билгеле Тәүратта әнә шул асылы бозылган, үзгәртелгән кайбер бүлекләр белән бергә беркадәр Хәзрәти Мусаның тормышы бәян ителгән.

**Сыерны корбан итеп чалу**

Исраил угылларыннан Гамил исемле бик бай бер кешенең үле гәүдәсе табыла. Аны туганнан туганнары үтергән була. Әлеге җинаять сәбәпләре мәсьәләсендә мондый риваятьләр бар:

1. Аны бик ярлы һәм саран икетуганнары байлыгына кызыгып үтергән.

2. Гамил бер хатынга өйләнгән була, агасының (әтисенең бертуганының) улы исә, шул хатынны үзенә алыр өчен, кардәше ярдәме белән Гамилне үтергән.

Җинаятьчеләр Гамилнең мәетен ике авыл арасына ташлап калдыра. Бу эш алар бер-берсе белән дошманлашсыннар өчен эшләнә. Халык, Хәзрәти Мусага мөрәҗәгать итеп, үтерүчене табуын һәм тиешле җәзасын бирүне сорый. Муса галәйһис-сәләәм Гамилне кем үтергәнлеге мәсьәләсендә икеләнеп кала һәм һичтөрле нәтиҗә чыгара алмый. Шуннан соң Аллаһка дога кыла. Аллаһ Тәгалә исә бер сыерны корбан итеп чалырга боера. Бәни Исраил Муса галәйһис-сәләәмгә: «Үтерүче белән сыер суюда нинди бәйләнеш бар?! Син бездән көләсеңме әллә?» – дип ризасызлык белдерә. Асылда, бу ризасызлыклары аркасында алар, үзләре дә сизмичә, Хак Тәгалә әмеренә буйсынудагы хата-кимчелекләре сәбәпле, Аның каршында сынау бирә башлый.

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм кавеменә: «Мин Раббым кушканны гына белдерәм!» – дип аңлата.

Аяти кәримәдә бу вакыйга болай тасвирлана:

وَإِذْ قَالَ مُوسَى لِقَوْمِهِ إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُكُمْ أَنْ تَذْبَحُوا بَقَرَةً قَالُوا أَتَتَّخِذُنَا هُزُواً قَالَ أَعُوذُ
بِاللَّهِ أَنْ أَكُونَ مِنَ الْجَاهِلِينَ. قَالُوا ادْعُ لَنَا رَبَّكَ يُبَيِّنْ لَنَا مَا هِيَ قَالَ إِنَّهُ يَقُولُ إِنَّهَا
بَقَرَةٌ لَا فَارِضٌ وَلَا بِكْرٌ عَوَانٌ بَيْنَ ذلِكَ فَافْعَلُوا مَا تُؤْمَرونَ. قَالُوا ادْعُ لَنَا رَبَّكَ يُبَيِّنْ
لَنَا مَا لَوْنُهَا قَالَ إِنَّهُ يَقُولُ إِنَّهَا بَقَرَةٌ صَفْرَاءُ فَاقِعٌ لَوْنُهَا تَسُرُّ النَّاظِرِينَ

**«Янә бервакыт Муса кавеменә: “Һичшиксез, Аллаһ сезгә бер сыер чалырга боера”, – диде дә, алар: “Син безне мыскыл итәсеңме әллә?” – дигәннәр иде». «Мин җаһилләрдән булудан Аллаһка сыенам», – диде. (Шуннан соң кавеме): «(Алайса) безнең өчен Раббыңа дога кыл. Ул безгә аның нинди булганын аңлатсын», – дигәннәр иде. Ул (Муса): «Һичшиксез, Ул: “Ул сыер бик карт та, бик яшь тә булмасын, болар арасындагы яшьләрдә, – диде. – Сез әмер ителгәнне үтәгез!”» – дип әйтте. Алар: «Безнең өчен Раббыңа дога кыл. Ул безгә аның төсе нинди булганын ачыкласын», – дигәннәр иде. Ул (Муса): «Һичшиксез, Ул: “Караучыларны шатландыра торган сап-сары төсле сыер”, дип әйтте”, – диде»** («әл-Бәкара», 67–69).

Яһүдиләр бу сыйфатларга туры килгән сыерны ятим баласы булган бер хатында табалар. Сыеры бар тормышын-яшәешен тәэмин итеп торганга, ул хатынның сыерны сатасы килми. Шунлыктан сыер өчен 1000 тәңкә сорый.

Муса галәйһис-сәләам: «Хатын сораган кадәр акча бирегез дә сыерны сатып алыгыз!» – дигәч, Исраил угыллары 1000 тәңкәгә ризалаша, ләкин бу юлы хуҗа хатын бәяне 2000 тәңкәгә кадәр күтәрә. Сыер хакын бик кыйбат, дип, кавемдәшләре малны сатып алмаска була һәм кабат Муса галәйһис-сәләамгә мөрәҗәгать итәләр:

قَالُوا ادْعُ لَنَا رَبَّكَ يُبَيِّنْ لَنَا مَا هِيَ إِنَّ الْبَقَرَ تَشَابَهَ عَلَيْنَا وَإِنَّآ إِنْ شَاءَ اللَّهُ لَمُهْتَدُونَ.
قَالَ إِنَّهُ يَقُولُ إِنَّهَا بَقَرَةٌ لَا ذَلُولٌ تُثِيرُ الْأَرْضَ وَلَا تَسْقِي الْحَرْثَ مُسَلَّمَةٌ لَا شِيَةَ فِيهَا
قَالُوا الْآنَ جِئْتَ بِالْحَقِّ فَذَبَحُوهَا وَمَا كَادُوا يَفْعَلُونَ

**«Алар: “(И, Муса!) Безнең өчен Раббыңа дога кыл. Ул безгә аның нинди икәнлеген аңлатсын, чөнки сыерлар бер-берсенә охшаш. Һичшиксез, без, әгәр Аллаһ теләсә, туры юлны табарбыз”, – дип әйттеләр». Ул (Муса): «Һичшиксез, Ул (Аллаһ), “шиксез, ул (сыер) – җир сукалап, иген сугарып эшләгән түгел, сау-сәламәт (ирекле йөргән) һәм бернинди төс катнашмаган сыер”, дип әйтте», – диде. Алар (Исраил угыллары бу юлы): «“Менә хәзер син хак китердең инде”, – диделәр һәм аны чалдылар. Әмма алар үтәмәүгә бик якын иделәр»** («әл-Бәкара», 70–71).

Исраил угыллары корбан чалуга бәйле әмерне үтәүдән баш тарта яза, аятьнең бу хактагы җөмләләре ятим бала тәрбияләүче хатынның сыерына ишарәли. Өстәвенә, ул хатын сыер бәясен шактый арттыра – 10000 тәңкәгә кадәр күтәрә. Соңыннан исә: «Бу малны алырсыз, аны суярсыз һәм тиресеннән капчык ясап, шуңа алтын тутырып миңа бирерсез! Сезгә сыерны бары әнә шул шарт белән генә сата алам», – дип белдерә.

Бәни Исраил кабат Хәзрәти Муса галәйһис-сәләамгә мөрәҗәгать итә. Ул исә: «Нинди бәягә булса да, алыгыз!» – дип киңәш бирә. Шуннан соң кавеме: «Алайса хәзер алыйк, кушылган эш үтәлсен, югыйсә соңыннан түли алмая-

чакбыз», – дип килешә. Ниһаять, сыерны сатып алалар. Җәнабел-Хак болай дип хәбәр итә:

وَإِذْ قَتَلْتُمْ نَفْسًا فَادَّارَأْتُمْ فِيهَا وَاللَّهُ مُخْرِجٌ مَا كُنْتُمْ تَكْتُمُونَ

**«Заманында сез бер кешене үтергән идегез һәм аның хакында сүз көрәштерә идегез. Аллаһ сез яшермәкче булган нәрсәне чыгаручы булды»** («әл-Бәкара», 72).

Ләкин Бәни Исраил бу юлы да сыер хакын түләмәскә маташа. Хәзрәти Муса: «Тиешле бәясен түләмәсәгез, үле терелмәячәк!» – ди. Башка чара калмагач, кавеме сыер тиресеннән капчык ясап, аның эченә алтын тутыра һәм сыер саткан хатынга илтеп бирә.

فَقُلْنَا اضْرِبُوهُ بِبَعْضِهَا كَذَلِكَ يُحْيِي اللَّهُ الْمَوْتَى وَيُرِيكُمْ آيَاتِهِ لَعَلَّكُمْ تَعْقِلُونَ

**«Без: "Аның (суелган сыерның) берәр әгъзасы белән аңа (үтерелгән кешегә) сугыгыз", – дигән идек. Аллаһ әнә шулай үлеләрне терелтә һәм (Пәйгамбәренә биргән) могҗизаларын сезгә күрсәтә, бәлки, сез аңларсыз»** («әл-Бәкара», 73).

Аяти кәримәдә: «Суелган сыерның берәр әгъзасы белән аңа (үтерелгән кешегә) сугыгыз», – дигән сүзләр бу вакыйгага тагын да зуррак игътибар җәлеп итү өчен әйтелгән. Шуңа күрә әнә шундый мәрасим оештырыла һәм аннары могҗиза чынга аша. Чынлыкта, әлбәттә, Аллаһ Тәгалә бернинди сәбәпсез дә үлеләрне терелтергә кодрәтле.

Ахырда, сыерның теле белән мәеткә кагылгач, канга баткан гәүдә торып баса да: «Мине агамның уллары үтерде. Болар – фәлән-фәләннәр...» – дип, җинаятьчеләрнең исемнәрен белдереп, хакыйкатьне ачыклап биргәч, кабат үлә.

**Бу кыйссадагы гыйбрәтләр**

*Исраил угыллары илаһи әмерне үтәгәндә, нәрсәгәдер ризасызлык белдергән саен, авырлыклары арта гына бара. Әгәр илаһи әмер килүгә үк, берәр сыерны суйган булсалар, Аллаһ кушкан гамәл үтәлгән булыр иде. Әмма өсте-өстенә бирелгән сораулар белән үҗәт кавем гүя моны эшләргә теләмәгән кебек кылана һәм мәсьәләне үз куллары белән катлауландыра. Шул рәвешле аларның еш каршы килүләре һәм үзләренә куелган чикләрне танымаулары аркасында, үзләре үк авыр нәтиҗәләргә дучар ителә.

*Кирәкмәс, урынсыз сораулар бирү рөхсәт ителми, тәкъдир һәм каза мәсьәләләрендә билгеләнгән чикне узып, тагын да тирәнрәк белергә теләгән кебек... Ягъни Аллаһ анык бер хөкем чыгарган мәсьәләдә буйсынып, итагать кылу тиеш. Чөнки кирәксез сораулар һәм ризасызлыклар яңа чикләүләр һәм

бурычлар гына алып килә, болар исә җаваплылыкның тагын да артуына, кыенлашуына сәбәп була.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

*«...Мин сезне үз иркегездә калдырган вакытта, сез дә мине үз иркемдә калдырыгыз. Чөнки сездән әүвәлгеләр пәйгамбәрләренә бик күп сораулар бирү һәм шуларга алган җавапларга бәйле рәвештә үзара килешә алмаулары аркасында һәлак булдылар. Шунлыктан сезгә бернәрсә кушкан чагымда, аны хәлегездән килгәнчә үтәгез. Нәрсәне дә булса тыям икән, аннан катгый рәвештә тыелыгыз!»* (Мөслим, «Хаҗ», 412).

*Исраил угыллары элегрәк бозауга табынганлыктан, аларга сыерны корбан итеп чалырга кушыла. Бу гамәл сыерда илаһилык, бөеклек юклыгын аңласыннар өчен башкарыла. Чөнки адәм баласы асылындагы коллык хис-тойгылары йогынтысында, кайчак, ялгышып, илаһны үзе яшәгән дөнья үлчәмнәре һәм үзенең аң-зиһен, сәләт-мөмкинлекләре кысасында эзләү тилелегенә чума ала.

*Илаһи әмергә буйсыну мәсьәләсендә Исраил угыллары эшне сузып, кушканны үтәүне кичектерә килгәндә, җинаятьчеләр берничек тә табылмый һәм шунлыктан ызгыш-талаш, гауга-бәхәсләр көчәя. Сыер корбанлыкка чалынып, үтерүчеләр ачыклангач, тынычлык урнаша.

*Исраил угылларының кайберләре «үлгәннән соң терелү» мөмкинлегенә икеләнә, ышанып бетми. Әлеге вакыйга исә мондый иман зәгыйфьлеген дә юкка чыгара.

**Пәйгамбәребезнең Мигъраҗда Хәзрәти Муса белән очрашуы**

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мигъраҗда Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм белән берничә тапкыр очраша. Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез Аллаһ Тәгалә катыннан илле вакыт намаз уку йөкләмәсе белән киткәч, Муса галәйһис-сәләәм Аңа: «Мин Синнән әүвәлрәк Исраил угылларында тәҗрибә ясадым. Илле вакыт намазга Синең өммәтеңнең көче җитмәс!» – дип, Җәнабел-Хактан илле вакытның азайтылуын сорарга киңәш бирә.

Шуннан соң Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм биш тапкыр Аллаһ Тәгаләгә мөрәҗәгать итә һәм намаз һәрьюлы бераз киметелеп, биш вакытка кадәр азайтыла.[134]

Бу вакыйгадагы хикмәтләрнең иң зурысы үткәннәрнең тәҗрибәсеннән файдалана белү кирәклегеннән гыйбарәт.

134. Карагыз: Бохари, «Саләт», 1; Мөслим, «Иман», 263.

**Карун**

Карун Хәзрәти Мусаның агасы (әтисенең бертуганы) яки агасының улы була. Тәүратны иң матур укуда Муса галәйһис-сәләәмнән генә калыша. Бик ярлы була, башкалар ярдәме белән генә тормыш алып бара. Хәзрәти Муса догасы бәрәкәтендә аңа алхимия, ягъни кыйммәтле матдәләрдән алтын ясау гыйлеме бирелә.

Муса галәйһис-сәләәмгә иман китергәнче, Карун Бәни Исраилнең Фиргавен янындагы вәкиле була. Ул үз кул астындагыларны кимсетеп, изеп йөри. Иман китергәннән соң, үзен гыйлемгә, хикмәткә һәм гыйбадәткә багышлый. Ләкин шайтан мәлгунь кеше кыяфәтендә аның янына килеп, дусты булуга ирешә. Аннары бер форсат табылган көнне дустанә бер мөнәсәбәт белән: «Әй, Карун! Башкалардан килгән керем белән яшәгәнче, атнага бер көн эшләп алыйк, алты көнен гыйбадәттә үткәрербез!» – ди. Бу фикер Карунның күңеленә хуш килә. Алар шәһәргә төшеп, бер көн эшләп алалар. Шушы бер көнлек хезмәтләренә алган түләү бәрабәренә алты көн яшәп, гыйбадәт кылалар. Тәүге ташламаны алуга ирешкән шайтан бу юлы: «Әй, Карун! Кара әле, берәүгә дә мохтаҗлык тоймадык! Әйдә, моннан соң атнаның яртысында акча эшлик, яртысында гыйбадәт кылырбыз! Ә эшләп тапкан акчаның артыгын Аллаһ юлында фәкыйрьләргә тоту мөмкинлегебез булыр!» – дип кыстый.

Инде бер юл бирә башлаган Карунга бу тәкъдим тагын да кызыклырак, файдалырак тоела һәм ул ризалаша. Шайтан хәйләсен чынга ашыруда уңышка ирешә һәм хезмәт кую вакытын шактый арттыра: «Тагын да күбрәк эшләп, күбрәк акча алыйк! Шул акча бәрабәренә гыйбадәт тә кылырбыз, күбрәк фәкыйрьне дә сөендерербез!» – дип өнди. Һәм әкренләп Карунның йөрәгенә дөньялыкка тартылу, бу дөньяга мәхәббәт кереп урнаша. Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм догасы белән бирелгән алхимия гыйлеме ярдәмендә бик баеп китә. Карунның йөрәге дөнья теләк-омтылышлары белән тула. Шулчакта бөтен күркәм һәм йомшак сыйфатларын югалта. Карун, масаеп, тәкәбберлеккә бирелә. Югыйсә байлыгы Хәзрәти Муса өйрәткән гыйлем бәрабәренә килә.

Аяти кәримәдә болай диелә:

إِنَّ قَارُونَ كَانَ مِنْ قَوْمِ مُوسَى فَبَغَى عَلَيْهِمْ وَآتَيْنَاهُ مِنَ الْكُنُوزِ مَا إِنَّ مَفَاتِحَهُ لَتَنُوءُ
بِالْعُصْبَةِ أُولِي الْقُوَّةِ إِذْ قَالَ لَهُ قَوْمُهُ لَا تَفْرَحْ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الْفَرِحِينَ

**«Һичшиксез, Карун Мусаның кавеменнән иде дә, алардан үзен өстен тотты (аларга каршы азгынлык кылды). Без аңа хәзинәләрдән шулкадәр биргән идек ки, аның ачкычларын көч ияләре булган бер җәмәгатькә дә авыр була иде. Менә каveме аңа әйткән иде: “Сөенмә! Һичшиксез, Аллаһ сөенүчеләрне сөйми!”»** («әл-Касас», 76).

Йөрәгеn дөнья теләкләре басып алган Карун хәзер инде Муса галәйһис-сәләәмнең үгет-нәсыйхәтләреннән туя; аның киңәшләрен тыңлый алмас хәлгә җитә. Һарун галәйһис-сәләәмгә һәм ул караган ләвиләр нәселенә корбан чалу вазифасы йөкләнгәч, Карунның йөрәгеn биләп алган яман сыйфатлар тышка бәреп чыга. Ул күңелендә кайнаган ачуга түзә алмыйча, Муса галәйһис-сәләәм янына килеп, ризасызлыгын белдерә: «Әй, Муса! Туганың Һарунга корбан чалу вазифасын биргәнсең. Минем исә андый сәләтем юк. Югыйсә мин Тәүратны бик әйбәт укыйм. Шуңа күрә мин Һаруннан өстенрәк! Мондый гаделсезлеккә ничек түзеп торыйм?!» Муса галәйһис-сәләәм исә җавабында: «Һарунга бу вазифа һәм урынны мин түгел, Җәнабел-Хак бирде!» – дип аңлата. Ләкин Карун үзсүзләнеп: «Миңа бирәр дәлил күрсәтмәсәң, моңа ышанмаячакмын!» – ди.

Муса галәйһис-сәләәм Бәни Исраил башлыкларын туплый да әмер бирә: «Таякларыгызны алып килегез! Барысын да билгеле бер урынга куярбыз. Кемнең таягы яфракланып яшеллек җибәрсә, корбан чалу эшенә шул лаек!»

Кавем башлыклары таякларны алып килеп, үзләре гыйбадәт кыла торган урынга куялар. Болар арасыннан Һарун галәйһис-сәләәмнең таягы гына яфракланып, яшеллек белән каплана.

Шушы ачык могҗиза нәтиҗәләре күренгәч, Муса галәйһис-сәләәм Карунга мөрәҗәгать итә: «Әй, Карун! Моны син эшләдеңме?». Карун аптырап кала. Эшнең асылын аңлаган килеш тә, ул нәфесенә буйсынып: «Бу сихерчелектән башка нәрсә була алмый!» – дип әйтә. Аннары бик ачулы кыяфәттә алар яныннан китеп бара.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Бәни Исраил кавеменә киемгә зәңгәр тасма тагып йөрергә куша. Карун моңа да каршы чыга: «Бу гадәт хуҗаларны колларыннан аеру өчен генә ул!» – дип, тасма тагуны кире кага.

Карунның Муса галәйһис-сәләәмгә карата ачу-нәфрәте шактый көчәя. Нәфесендәге көнчелек уты аны эчтән яндыра. Әйләнә-тирәдәгеләрнең игътибарын үзенә җәлеп итү, үз ягына аудару өчен, ул кунак мәҗлесләре оештыра һәм үзенең өстенлеге турында чыгышлар ясап, әңгәмәләр кора башлый.

Беркөнне Муса галәйһис-сәләәм, Аллаһның әмеренә ярашлы рәвештә, Карунга зәкят күләмен хисапларга һәм түләргә куша. Карун кызып китә: «Хәзер инде син малыма да күз төшердеңме? Бу байлыкны мин үзем эшләп алдым!»

Карунга мөрәҗәгать рәвешендә мондый аять иңә:

وَابْتَغِ فِيمَا آتَاكَ اللَّهُ الدَّارَ الْآخِرَةَ وَلَا تَنْسَ نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا وَأَحْسِنْ كَمَا
أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ وَلَا تَبْغِ الْفَسَادَ فِي الْأَرْضِ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الْمُفْسِدِينَ

**«Аллаһ сиңа биргән нәрсәләрдә (Аның юлында сарыф итеп) соңгы йортны эзлә. Дөньяңнан да насыйбыңны онытма! Аллаһ сиңа игелек кылганы кебек, син дә (кешеләргә) игелек кыл. Җирдә бозыклык эзләмә. Һичшиксез, Аллаһ бозыклык чыгаручыларны сөйми!»** («әл-Касас», 77).

قَالَ إِنَّمَا أُوتِيتُهُ عَلَى عِلْمٍ عِندِي أَوَلَمْ يَعْلَمْ أَنَّ اللّٰهَ قَدْ أَهْلَكَ مِنْ قَبْلِهِ مِنَ الْقُرُونِ مَنْ هُوَ
أَشَدُّ مِنْهُ قُوَّةً وَأَكْثَرُ جَمْعًا وَلَا يُسْأَلُ عَنْ ذُنُوبِهِمُ الْمُجْرِمُونَ. فَخَرَجَ عَلَى قَوْمِهِ فِي زِينَتِهِ
قَالَ الَّذِينَ يُرِيدُونَ الْحَيٰوةَ الدُّنْيَا يَا لَيْتَ لَنَا مِثْلَ مَا أُوتِيَ قَارُونُ إِنَّهُ لَذُو حَظٍّ عَظِيمٍ. وَقَالَ
الَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ وَيْلَكُمْ ثَوَابُ اللّٰهِ خَيْرٌ لِمَنْ آمَنَ وَعَمِلَ صَالِحًا وَلَا يُلَقَّيهَا إِلَّا الصَّابِرُونَ

**«(Карун:) “Ул (байлык) миңа янымда булган бер гыйлем сәбәпле бирелгән”, – диде. Аллаһның аннан алдагы гасырлардан куәт ягыннан аңардан көчлерәк, туплау ягыннан да күбрәк булганнарны һәлак иткәнен белмиме әллә ул? Гөнаһлылар гөнаһларыннан соралмаячаклар (Аллаһ аларның барысын да белә). Ул (Карун) зиннәте эчендә кавеменең каршысына чыкты. Дөнья тормышын теләгәннәр: “Их, Карунга бирелгәннең охшашы бездә дә булса иде! Һичшиксез, ул зур бер насыйп иясе”, – диде. Үзләренә гыйлем бирелгән кешеләр исә: “Ни үкенеч сезгә! Аллаһның савабы иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр өчен яхшырак”, – диде. Моңа исә сабыр иткәннәр ирешер»** («әл-Касас», 78–80).

**Шакшы яла**

Беркөнне Карун Бәни Исраил кавемен җыя. Муса галәйһис-сәләәмне дә чакыра һәм: «Әй. Муса! Хәзер син Аллаһның менә мондый хөкемнәрен безгә аңлат: урлашкан кешегә, зина кылучыга нинди җәза бирелер? Мондый гамәлләрне син кылсаң, сине ни көтә?!» – ди. Хәзрәти Муса: «Каракның кулы киселәчәк, зиначы таш белән үтереләчәк!» – ди.

Карун кабат: «Ә боларны син эшләгән булсаң?!» – дип сорый. Муса галәйһис-сәләәм: «Бары шул ук җәза!» – дип җавап бирә.

Алдан ук мәкерле план корып куйган Карун халык төркеме арасыннан бер хатынга дәшә: «Әй, ханым, кил әле! Кил дә Муса белән бергә эшләгән оятсыз, әшәке гамәлегез турында сөйлә!»

Мондый пычрак яла Муса галәйһис-сәләәмнең бик ачуын чыгара, ул бик кызып китә. Шулвакытта теге хатын да болар янына килеп җитә. Ул нидер сөйләргә тели, ләкин теле тотлыга, сөйли алмый. Хәзрәти Муса ачу катыш аңа сорау яудыра: «Әй, ханым! Диңгезне ярып юл ачкан һәм Тәүратны индергән Аллаһ хакы өчен дөресен сөйлә. Мин сине беләмме? Синең белән берәр нинди бәйләнешем бармы?»

Теге хатын, бик нык үкенеп, дөреслекне ачып бирә: «Йә, Муса! Карун миңа күп итеп акча бирде һәм сиңа шушы яланы ягарга күндерде». Шуннаң соң бик зур үкенеч тоеп, тәүбә итә. Муса галәйһис-сәләәм сәҗдәгә каплана да: «Йә, Раббы! Боларга тиешле җәзаны бир!» – дип дога кыла.

Әлеге бәддогадан соң җир ярыла. Оятсыз планы җимерелеп, үзенә кайткан Карун һәм аның тарафдарлары бөтен байлыклары белән бергә җир астына китә.

Җәнабел-Хак болай ди:

فَخَسَفْنَا بِهِ وَبِدَارِهِ الْأَرْضَ فَمَا كَانَ لَهُ مِنْ فِئَةٍ يَنْصُرُونَهُ مِنْ دُونِ اللهِ وَمَا كَانَ مِنَ الْمُنْتَصِرِينَ

**«(Ниһаять), аны да, өен дә җирдән йоттырдык. Һәм Аллаһтан башка аңа ярдәм итә алган аның кешеләре булмады. Ул үз-үзенә ярдәм итә алмады»** («әл-Касас», 81).

Карунны дөньялыкка мөкиббән китүе һәм бүтәннәрдә булган нигъмәтләргә көнләшүе һәлак итә. Шуңа да аяти кәримәдә көнчеләрнең явызлыгыннан Аллаһка сыгынуыбыз кирәклеге бер дога рәвешендә белдерелә:

قُلْ أَعُوذُ بِرَبِّ الْفَلَقِ. مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ. وَمِنْ شَرِّ غَاسِقٍ إِذَا وَقَبَ.
وَمِنْ شَرِّ النَّفَّاثَاتِ فِي الْعُقَدِ. وَمِنْ شَرِّ حَاسِدٍ إِذَا حَسَدَ

**«Әйт: “Таңның Раббысына сыенамын. Ул яралткан нәрсәләрнең зарарыннан. Каплаган чакта куе караңгылык (төн) зарарыннан. Төеннәргә өргән җаннарның зарарыннан да. Янә көнләшүченең көнләшкән чагындагы зарарыннан да!”»** («әл-Фәләкъ», 1–5).

Көнләшүчеләрне исә бары авыр язмыш, кайгы-хәсрәт кенә көтә.

Бәни Исраил халкы, Карун һәм аның яраннарының һәлак ителүен күргәч, аңа охшарга тырышуларына, аннан үрнәк алуларына бик үкенәләр:

وَأَصْبَحَ الَّذِينَ تَمَنَّوْا مَكَانَهُ بِالْأَمْسِ يَقُولُونَ وَيْكَأَنَّ اللهَ يَبْسُطُ الرِّزْقَ لِمَنْ يَشَاءُ مِنْ عِبَادِهِ وَيَقْدِرُ لَوْلَا أَنْ مَنَّ اللهُ عَلَيْنَا لَخَسَفَ بِنَا وَيْكَأَنَّهُ لَا يُفْلِحُ الْكَافِرُونَ. تِلْكَ الدَّارُ الْآخِرَةُ نَجْعَلُهَا لِلَّذِينَ لَا يُرِيدُونَ عُلُوًّا فِي الْأَرْضِ وَلَا فَسَادًا وَالْعَاقِبَةُ لِلْمُتَّقِينَ

**«Кичә генә аның урынында булырга теләгән кешеләр: “Ай! Аллаһ колларыннан теләгәненә ризыкны киңәйтә һәм тарайта! Аллаһ безгә игелек кылмаган булса, безне дә (җир астына) йоттырган булыр иде. Ай-һай! Кяферләр уңышка ирешмәс”, – дия башлады. Ул – соңгы йорт (ахирәт йорты). Без аны җирдә тәкәбберләнмәгән һәм бозыклык теләмә-**

**гәннәрнеке итәчәкбез. Ул (иң күркәм) нәтиҗә тәкъвалык ияләренеке»** («әл-Касас», 82–83).

Карун кыйссасында өммәткә бер гыйбрәт буларак, тәкәббер, көнче кешенең һәм ахирәтне онытып, бу дөнья рәхәтлекләренә чумучыларның ачы язмышы күрсәтелә.

Әлеге кыйссадагы яла ягу мәсьәләсе белән бәйле рәвештә суфи галимнәр мондый фикер белдерә:

Муса галәйһис-сәләәмнең элегрәк илаһи вәхигә нигезләнмәгән гамәле, ягъни Фатунны җиңелчә этеп җибәреп, аның үлеменә бер сәбәп булуы, Мусаның күңел дөньясын бик тетрәндерә. Әнә шул вакыйга сәбәпле хәтта Җәнабел-Хак та аңа: **«Син бер кешене үтердең!»** – турыдан-туры әйтә («Та-һә», 40). Ягъни Хак Тәгалә аны: «Безнең тарафтан вәхи, әмер-рөхсәтебез булмый торып, син ул кыптыйның җанын кыйдың!» – дип гаепли, шелтәли, дияргә мөмкин.

Менә шул очлы энә гел калкып чыгып, Хәзрәти Муса күңеленә кабат-кабат төртелә. Асылда ул теге чактагы гамәлен явызлык белән эшләми, ләкин үз белдеге белән башкарган бу эше һич кылмаган гамәлләрдә яла ягуга китерә. Шуңа күрә галимнәр: «Илаһи әмерләргә нигезләнмичә, үз белдегең белән эшләргә яратуны башыңнан чыгарып ташламасаң, сине үз кылычың (үз кораларың) белән чистартырлар һәм үз кылычың белән үтерелерсең, башкача була алмый!» – дигәннәр.

### Муса галәйһис-сәләәм белән Хозыр галәйһис-сәләәм

Фиргавен Кызыл диңгездә батып үлгәннән соң, Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм, кавеменә бик күркәм, аңлаешлы, тәртипле һәм дулкынландыргыч вәгазьләр сөйли башлый. Кавеме Хәзрәти Мусаның гыйлеменә, Аллаһны танып-белүдәге тирәнлегенә хәйран кала, бик сөенә. Араларыннан берсе: «И, Аллаһның пәйгамбәре! Шушы җир йөзендә синнән дә гыйлемлерәк башка бер зат бармы?» – дип сорап куя. Хәзрәти Муса: «Андый һичкемне белмим!» – дип әйтә. Шулвакытта аңа вәхи аша: «Ике диңгез тоташкан җирдә бер колым бар, аңа ашерен гыйлем биргән идем. Өммәтеңнең алдынгы, иманлы затларыннан берәрсе белән шуның янына бар!» – дигән әмер кылә.

Монда Хозыр галәйһис-сәләәм турында сүз бара.

Хәзрәти Муса: «Мин синең ул колыңны ничек таба алам соң, йә, Раббы?» – дип ялварып сорый. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү букчасына бер тозланган үле балык салырга боера. Бу балык, терелеп, диңгезгә сикергән, ике диңгез тоташкан урында Хозырны табачагын белдерә».

Муса галәйһис-сәләәм, риваятькә күрә, апасының улы Юша ибне Нун белән бергә Хозырны табу өчен сәфәргә кузгала. Аяти кәримәдә бу вакыйга турында түбәндәгечә искә алына:

وَإِذْ قَالَ مُوسَى لِفَتَاهُ لَا أَبْرَحُ حَتَّى أَبْلُغَ مَجْمَعَ الْبَحْرَيْنِ أَوْ أَمْضِيَ حُقُبًا

**«Менә Муса яшь юлдашына: “Мин ике диңгез кушылган җиргә барып җиткәнчегә кадәр туктамаячакмын, гәрчә еллар үтсә дә”, – дигән иде»** («әл-Кәһф», 60).

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ, әлеге вакыйганың гыйбрәтле һәм хикмәтле нокталарына игътибар юнәлтеп, түбәндәгечә тасвирлый:

«Әй, кәрим зат! Мондый рухи омтылышны “Кәлимуллаһ” булган Хәзрәти Мусада күреп, үрнәк ал! Кара, сүз остасы булган Муса галәйһис-сәләәм ни дип әйтә: “Шундый урын-дәрәҗәгә ия булсам да, үземдә байлык, кыйммәт сизмим. Җанымны тагын да киңрәк яктыртачак Хозырны эзлим”».

Муса галәйһис-сәләәм Хозырны эзләп табарга карар биргәннән соң, кавеме аңа: «Әй, Муса, син кавемеңне ташлагансың. Синнән түбәнрәк дәрәҗәдә торган бер затны эзли чыгарга телисең! Югыйсә син “хәвеф” (курку-шикләнүдән) һәм “рәҗа”дан[135] котылган бер пәйгамбәр. Тагын никадәр бәрелеп-сулыгып йөрергә, тагын күпме һәм кайчанга кадәр эзләргә җыенасың? Ул эзләгән нәрсәң синең үзеңдә... Моны үзең дә беләсең. Йә, күкләрдәй биек пәйгамбәр! Үзеңне тагын күпме шулай түбәнсетеп йөрерсең икән?»

Муса галәйһис-сәләәм кавеменә: «Кояш белән Ай юлына аркылы төшмәсәгез иде! Мин – пәйгамбәрлекнең ае, Хозыр исә әүлиялык кояшы. Ягъни миннән өстенрәк пәйгамбәрләр бар. Хозыр исә әүлияларның иң югары дәрәҗәсендә», – дип җавап бирә. Аннары сүзен дәвам итә: «Мин үз заманының солтаны булган бер әүлия белән сөйләшү өчен ике диңгез кушылган урынга барам. Хакыйкать һәм мәгърифәткә ирешү өчен, Хозырны бер этәргеч, сылтау итәчәкмен. Шуңа күрә сәфәрем озакка сузылачак. Башта аның белән кавышыйм әле. Тырышлык һәм ихтыяр көче канатларында еллар буе очачакмын. Еллар гына, дию аз, меңнәрчә ел барсам да, барыбер аны эзләп табачакмын. Бу сәфәр әнә шул җәүһәрне табу кыйммәтенә тормасмыни?»

Муса галәйһис-сәләәм һәм Юша ибне Нун:

فَلَمَّا بَلَغَا مَجْمَعَ بَيْنِهِمَا نَسِيَا حُوتَهُمَا فَاتَّخَذَ سَبِيلَهُ فِي الْبَحْرِ سَرَبًا

**«Алар (икесе дә) ике диңгез кушылган җиргә барып җиткәч, балыкларын оныттылар. Бу (балык), су астыннан бер юл табып, диңгезгә китте»** («әл-Кәһф», 61).

Бер риваятькә күрә, тукталыш ясап ял иткән вакытта, Муса галәйһис-сәләәм йоклаган арада, Юша ибне Нун балыкның кинәт җанланып, суга сикергәнен күреп кала. Ләкин бу хакта Хәзрәти Мусага әйтергә оныта. Йокы-

135. Рәҗа – тасаувыфта бәндәнең Аллаһ рәхмәтенә ышанып, һәрдаим өмет эчендә булуы.

дан уянгач, Муса галәйһис-сәләәм: «Әйдә, юлыбызны дәвам итик, бәлки, әле барасы юлыбыз ерактыр!..» – ди. Бергәләп сәфәрләрен дәвам итәләр. Шактый озак баргач, ниһаять, бер агач астына килеп утыралар.

فَلَمَّا جَاوَزَا قَالَ لِفَتَيهُ آتِنَا غَدَاءَنَا لَقَدْ لَقِينَا مِنْ سَفَرِنَا هَذَا نَصَبًا

**«(Очрашу урынын) узып киткәч, ул (Муса) егеткә: “Төшке ашыбызны китер, (бу) сәфәребез безне (шактый) алҗытты”, – диде»** («әл-Кәһф», 62).

Юша ибне Нун, шундук исенә төшереп: Мин аларны балык диңгезгә сикергән урында онытып калдырдым бит!» – ди.

قَالَ أَرَأَيْتَ إِذْ أَوَيْنَا إِلَى الصَّخْرَةِ فَإِنِّي نَسِيتُ الْحُوتَ وَمَا أَنْسَانِيهُ إِلَّا الشَّيْطَانُ أَنْ أَذْكُرَهُ وَاتَّخَذَ سَبِيلَهُ فِي الْبَحْرِ عَجَبًا. قَالَ ذَلِكَ مَا كُنَّا نَبْغِ فَارْتَدَّا عَلَى آثَارِهِمَا قَصَصًا. فَوَجَدَا عَبْدًا مِنْ عِبَادِنَا آتَيْنَاهُ رَحْمَةً مِنْ عِنْدِنَا وَعَلَّمْنَاهُ مِنْ لَدُنَّا عِلْمًا

**«Ул (егет): “Күрәмсең, кыя янында туктаган чагыбызда балыкны онытканмын. Аны миңа искә төшерергә, һичшиксез, шайтан комачаулады. Ә ул, юл табып, гаҗәеп рәвештә диңгезгә кереп китте”. Ул (Муса): “Менә без эзләгән нәрсә (урын) шул иде бит”, – диде, һәм икесе дә барган эзләреннән кире кайттылар. Алар колларыбыздан бер колны таптылар, Без аңа хозурыбыздан бер рәхмәт биргән, Үзебездән бер гыйлем өйрәткән идек»** («әл-Кәһф», 63–65).

Тәсаувыфтагы «ләдүнни гыйлем» гыйбарәсе менә шушы аятьтән алынган. Тәсаувыф гыйлеме кешеләрнең бер өлешенә генә хас һәм аның асылы тәкъвалыктан, ихсанлык тойгысына ирешүдән гыйбарәт. Ягъни бу гыйлем күңел дөньясына карый. Шул ук вакытта кешенең бу мәсьәләдә табигый омтылышы, күнекмәсе һәм сәләте генә түгел, җаваплылыгы да мөһим. Бәндә үзенең сәламәтлеге өчен бу күнекмәсен үстерергә тиеш. Моны исә нәфесне тәрбияләү һәм пакьләү аша башкарырга мөмкин. Ләдүнни гыйлемгә исә тәсаувыфта рухи тәрбия нәтиҗәсендә ирешелә һәм ул Хак Тәгалә тарафыннан бирелгән гыйлем санала. Аны тышкы яктан күренеп торган, ачык гыйлем ярдәмендә өйрәнеп булмый.

Хозыр галәйһис-сәләәм турында Җәнабел-Хак:

وَعَلَّمْنَاهُ مِنْ لَدُنَّا عِلْمًا

**«…Без аңа Үзебездән бер гыйлем өйрәткән идек!»** – дип әйтә («әл-Кәһф», 65).

«Бәкара» сүрәсендә Аллаһ Тәгаләнең мондый аяте бар:

وَاتَّقُوا اللّٰهَ وَيُعَلِّمُكُمُ اللّٰهُ

**«...Аллаһтан куркыгыз. Аллаһ сезгә (кирәкле нәрсәләрне) өйрәтә...»** («әл-Бәкара», 282).

Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһедән риваять кылына: «Хакыйкать гыйлеме Аллаһ Җәллә Җәләлүһү серләреннән бер сер һәм Аның хикмәтләреннән берникадәр хикмәт дигән сүз, ул гыйлемне (Аллаһ Үзе) теләгән колларының күңеленә салыр» (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 52).

Муса галәйһис-сәләәм үзенә вәхи белән күрсәтелгән затны бер кыя-тау өстендә чапанына төренеп басып торган хәлдә очрата һәм аңа сәлам биреп: «Мин Муса булам!» – дип, үзе белән таныштыра. Хозыр галәйһис-сәләәм җавабында: «Димәк, Бәни Исраил кавеме пәйгамбәре булган Муса син инде ул!» – ди. Муса галәйһис-сәләәм: «Миңа Аллаһ тарафыннан белдерелгән, кешеләрнең иң галиме булган зат синме ул?» – дип сорый. Хозыр галәйһис-сәләәм җавабында: «Йә, Муса! Аллаһ миңа бертөрле гыйлем биргән, ул синдә юк. Сиңа да бер гыйлем биргән, анысы миндә юк», – дип аңлаткан.[136]

Муса галәйһис-сәләәм Хозыр галәйһис-сәләәмнән бу гыйлемне үзләштерү теләге барлыгын белдерә. Гади акыл белән аңлау мөмкин булмаган кайбер гаҗәеп хакыйкатьләрнең хикмәтен ул Хозырдан өйрәнергә ниятли.

قَالَ لَهُ مُوسَى هَلْ أَتَّبِعُكَ عَلَى أَنْ تُعَلِّمَنِ مِمَّا عُلِّمْتَ رُشْدًا

**«Муса аңа әйтте: “Үзеңә өйрәтелгән гыйлемнән (һәм хикмәттән) туры юл турында миңа да өйрәтүең өчен мин сиңа иярсәм буламы?”»** («әл-Кәһф», 66) Хозыр галәйһис-сәләәм:

قَالَ إِنَّكَ لَنْ تَسْتَطِيعَ مَعِيَ صَبْرًا. وَكَيْفَ تَصْبِرُ عَلَى مَا لَمْ تُحِطْ بِهِ خُبْرًا

**«Ул әйтте: “Син минем белән бергә сабыр итә алмассың. Колачлый алмаган бер гыйлемгә ничек сабыр итәрсең?”»** («әл-Кәһф», 67–68).

Бу сүзләре белән Хозыр галәйһис-сәләәм Хәзрәти Мусаның психологик халәте турында беренче тапкыр аңлатма бирә. Бер яктан караганда, бу хакта аның үзенә аңлата һәм әйткәннәре соңыннан чынга аша. Хәзрәти Муса моннан алырга тиешле сабак үз урынын белү кирәклегеннән һәм сабырлык күрсәтүдән гыйбарәт. Ягъни Хозыр галәйһис-сәләәм Хәзрәти Мусага әлеге үрнәк нигезендә: «Минем белән бертигез дәрәҗәдә сабыр итү синең хәлеңнән килмәс. Бу мәсьәләдә син гозерле саналасың, чөнки бу гыйлемнең иң зур дәрәҗәсе әле сиңа бирелмәгән», – дип белдерә.

Муса галәйһис-сәләәм:

136. Карагыз: Бохари, «Тәфсир», 18/2, 3, 4; «Әнбия», 27; Мөслим, «Фәдаил», 170/2380.

قَالَ سَتَجِدُنِي إِنْ شَاءَ اللَّهُ صَابِرًا وَلَا أَعْصِي لَكَ أَمْرًا

**«Ул: “Иншә Аллаһ, син минем сабыр булганымны күрерсең. Синең бер әмереңә дә каршы килмәм”, – диде»** («әл-Кәһф», 69).

Хозыр галәйһис-сәләәм: «Әгәр миңа иярсәң, мин сиңа серне ачканчы, миннән һичнәрсә турында сорама! Бәхәсләшү турында сүз дә була алмый, хәтта нәрсәнедер аңлау өчен дә сорау бирмә!» – ди.

قَالَ فَإِنِ اتَّبَعْتَنِي فَلَا تَسْأَلْنِي عَنْ شَيْءٍ حَتَّى أُحْدِثَ لَكَ مِنْهُ ذِكْرًا

**«Ул (изге кол): “Әгәр дә миңа иярсәң, сиңа бәян иткәнче берни турында да миннән сорама”, – дип әйтте»** («әл-Кәһф», 70).

Һәм алар үзләренең атаклы сәфәрләренә кузгала. Коръәни-Кәрим аятьләрендә хикмәт һәм гыйбрәт тулы бу сәфәр түбәндәгечә бәян кылына:

فَانْطَلَقَا حَتَّى إِذَا رَكِبَا فِي السَّفِينَةِ خَرَقَهَا قَالَ أَخَرَقْتَهَا لِتُغْرِقَ أَهْلَهَا لَقَدْ جِئْتَ شَيْئًا إِمْرًا. قَالَ أَلَمْ أَقُلْ إِنَّكَ لَنْ تَسْتَطِيعَ مَعِيَ صَبْرًا. قَالَ لَا تُؤَاخِذْنِي بِمَا نَسِيتُ وَلَا تُرْهِقْنِي مِنْ أَمْرِي عُسْرًا

**«(Шуннан соң) алар икесе киттеләр. Көймәгә утыргач, (Хозыр) анда тишек ясады. Ул (Муса): “Моның халкын суга батырыр өчен тишек тиштеңме? Һичшиксез, син (зарары) зур бер эш эшләдең”, – дип әйтте. Ул (Хозыр): “Мин Минем янда сабырлыгың җитмәс”, дип әйтмәдемме?» – диде. Ул (Муса): “Онытканым өчен мине гаеп итмә һәм мине көчемнән килмәгән авырлыклар күтәрергә мәҗбүр итмә”, – диде»** («әл-Кәһф», 71–73).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

*«Шул рәвешле Хәзрәти Муса беренче тапкыр аңа әйтелгән сүзне оныта. Шулчакта бер чыпчык көймә читенә килеп куна һәм аннары, су эчәр өчен, томшыгын диңгезгә чумдыра. Шуннан соң Хозыр галәйһис-сәләәм Хәзрәти Мусага: “Аллаһның гыйлеме янында синең, минем һәм бөтен мәхлукларның гыйлеме шушы кошның диңгездән томшыгы белән алган су кадәр”, – дип чагыштыра»* (Бохари, «Тәфсир», 18/2–4).

فَانْطَلَقَا حَتَّى إِذَا لَقِيَا غُلَامًا فَقَتَلَهُ قَالَ أَقَتَلْتَ نَفْسًا زَكِيَّةً بِغَيْرِ نَفْسٍ
لَقَدْ جِئْتَ شَيْئًا نُكْرًا. قَالَ أَلَمْ أَقُلْ لَكَ إِنَّكَ لَنْ تَسْتَطِيعَ مَعِيَ صَبْرًا. قَالَ إِنْ سَأَلْتُكَ
عَنْ شَيْءٍ بَعْدَهَا فَلَا تُصَاحِبْنِي قَدْ بَلَغْتَ مِنْ لَدُنِّي عُذْرًا

**«Алар икесе янә киттеләр. Ниһаять, бер ир бала очраттылар. Ул (Хозыр) аны шунда ук үтерде. Ул (Муса): “Ничек син кыйсас (сәбәп,**

**каршылык) булмый торып, саф бер җанны үтерәсең? Һичшиксез, син гаеп итәрлек бик зур эш эшләдең", – диде. Ул (Хозыр): "Мин Минем янда (булачакларга) сабырлыгың җитмәс, дип әйтмәдемме?" – диде. Ул (Муса): "Әгәр моннан соң синнән берәр нәрсә сорасам, бүтән мине юлдаш итмәссең. Һичшиксез, син минем тарафтан (сылтау итеп атарлык) гозергә ирештең", – диде»** («әл-Кәһф», 74–76).

Бу сүзләре белән Хәзрәти Муса инде башка гафу сорарлык хәле калмаганын әйтергә теле.

فَانْطَلَقَا حَتَّى إِذَا أَتَيَا أَهْلَ قَرْيَةٍ اسْتَطْعَمَا أَهْلَهَا فَأَبَوْا أَنْ يُضَيِّفُوهُمَا
فَوَجَدَا فِيهَا جِدَارًا يُرِيدُ أَنْ يَنْقَضَّ فَأَقَامَهُ قَالَ لَوْ شِئْتَ لَاتَّخَذْتَ عَلَيْهِ أَجْرًا.
قَالَ هَذَا فِرَاقُ بَيْنِي وَبَيْنِكَ سَأُنَبِّئُكَ بِتَأْوِيلِ مَا لَمْ تَسْتَطِعْ عَلَيْهِ صَبْرًا

**«Янә икәү киттеләр. Бер шәһәр (авыл) халкына барып җитеп, алардан ашарга сорадылар. Ләкин алар (халык) боларны кунак итүдән баш тартты. Алар анда авып китәргә торган бер койма таптылар. Ул (Хозыр) аны тотты да турайтты. Ул (Муса): "Теләгән булсаң, моның өчен түләү алган булыр идең", – диде. (Хозыр) әйтте: "Бу – минем белән синең юллар аерылу чиге. Синең миңа сабыр итә алмаган нәрсәләрнең аңлатмасын ачыклаячакмын!"»** («әл-Кәһф», 77–78).

أَمَّا السَّفِينَةُ فَكَانَتْ لِمَسَاكِينَ يَعْمَلُونَ فِي الْبَحْرِ فَأَرَدْتُ أَنْ أَعِيبَهَا وَكَانَ وَرَاءَهُمْ مَلِكٌ
يَأْخُذُ كُلَّ سَفِينَةٍ غَصْبًا. وَأَمَّا الْغُلَامُ فَكَانَ أَبَوَاهُ مُؤْمِنَيْنِ فَخَشِينَا أَنْ يُرْهِقَهُمَا طُغْيَانًا
وَكُفْرًا. فَأَرَدْنَا أَنْ يُبْدِلَهُمَا رَبُّهُمَا خَيْرًا مِنْهُ زَكوةً وَأَقْرَبَ رُحْمًا.

**«Көймәгә килгәндә, ул фәкыйрь кешеләрнеке иде, алар диңгездә эшлиләр иде. Аны кимчелекле итәргә теләдем, чөнки аларның алларында бер хөкемдар бар ки, ул һәр (ныклы) көймәне талап ала иде. Ир балага килгәндә, аның ата-анасы иманлы кешеләр иде. Әмма без аның (баланың) ул икәүгә дә азгынлыгы белән авырлык һәм көферлек китерер, дип курыктык. Раббылары аларга сафлык ягыннан аңардан хәерлерәк һәм мәрхәмәтлерәкне бирсен, дип теләдек»** («әл-Кәһф», 79–81).

وَأَمَّا الْجِدَارُ فَكَانَ لِغُلَامَيْنِ يَتِيمَيْنِ فِي الْمَدِينَةِ وَكَانَ تَحْتَهُ كَنْزٌ لَهُمَا وَكَانَ أَبُوهُمَا
صَالِحًا فَأَرَادَ رَبُّكَ أَنْ يَبْلُغَا أَشُدَّهُمَا وَيَسْتَخْرِجَا كَنْزَهُمَا رَحْمَةً مِنْ رَبِّكَ وَمَا فَعَلْتُهُ
عَنْ أَمْرِي ذلِكَ تَأْوِيلُ مَا لَمْ تَسْطِعْ عَلَيْهِ صَبْرًا

**«Койма исә, ул шәһәрдә яшәгән ике ятимнеке иде. Аның астында алар өчен бер хәзинә бар. Аталары игелекле кеше иде. Синең Раббың**

**икесе дә көчле яшькә ирешүләрен һәм, Раббыңнан бер рәхмәт буларак, хәзинәләрен табуларын теләде.[137] Мин боларның берсен дә үз теләгем белән эшләмәдем. Син сабыр итә алмаган нәрсәләрнең аңлатмасы менә бу»** («әл-Кәһф», 82).

Әбү Зәррр радыйаллаһу ганһедән тапшырылган риваятькә күрә, дивар астындагы хәзинә белән бәйле рәвештә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: *«Аллаһ Тәгалә Үз китабында искә алган “кәнз” (хәзинә) алтыннан коелган тигез, шоп-шома тактадан гыйбарәт һәм анда: “Язмышка ышанып та, кайгырган һәм бик арыган-ялыккан хәлдә булучыларга аптырыйм. Җәһәннәмне һич онытмаган килеш тә, күп көлә торган кешенең дә ник көлгәненә аптырыйм. Үлемне искә төшергән чакта, гафләттә калучыга да аптырыйм. Лә иләһе илләллаһ, Мөхәммәдүн Рәсүлүллаһ” дип язып куелган»* (Ибне Кәсир, «Кыйсасүл-Әнбия», 424 б.).

Димәк, башка төрле гыйлемнәрдә аларны өйрәнүнең яртысын формалаштырган сорау бирү ысулы ләдүнни гыйлемдә тыела. Монда укучының җаны эш-гамәл, тырышлыкка караганда, күбрәк сәләте нигезендә тәрбияләнә һәм белем ала.

Мәсәлән, Мигъмар Синанның гыйлем куәте һәм сәләте «Сөләймания» мәчете төзелешендә эшләгән бөтен сәнгатькярләрнекеннән өстенрәк була. Шул ук вакытта Синанның ул мәчеттәге берәр мәрмәр остасы кебек мәрмәр эшкәртү сәнгатен белмәве атаклы мигъмар өчен кимчелек дип каралмый. Чөнки ул сәнгатькярләр дә Синан кушканны үтиләр. Мәрмәр эшкәртү сәнгатенең нечкәлекләрен алар барыбер Синаннан өйрәнә.

Үлүл-газыйм пәйгамбәр булган Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәмнең Хозыр галәйһис-сәләәм янына ләдүнни гыйлем өйрәнү өчен җибәрелүе, чыннан да, игътибарны җәлеп итә. Ләдүнни гыйлемгә ия бер заттан бу гыйлемгә өйрәнү Муса галәйһис-сәләәм өчен гаеп эш түгел. Шул ук вакытта Хәзрәти Мусаның бөтен нәрсәне дә белүче пәйгамбәр булмаганлыгы, Аллаһ гыйлемнәреннән аңа бирелмәгән әле тагы бик күп гыйлемнәр барлыгы турында хәбәр ителә. Бу гыйлемнең Мусадан түбәнрәк дәрәҗәдәге Хозыр аша бирелүе исә хәтта пәйгамбәрләрнең дә илаһи гыйлем каршында гаҗиз, көчсез хәлдә булганнарын күрсәтә. Тагын бер хикмәт шуннан гыйбарәт: Хәзрәти Муса белән Хозыр икесе бергә ия булган уртак гыйлем киләчәктәге «Зүл-Җәнахайн», ягъни дөнья

137. Хозыр галәйһис-сәләәм бу өч вакыйганың хикмәте турында сөйләгәндә, «Аны кимчелекле итәргә теләдем», «(Без) теләдек», «Раббың теләде» дип, өч төрле башкаручыны (субъект) телгә ала. Суфилар бу гыйбарәләрнең әүлияларга хас үз-үзеңне өч төрле тоту рәвешенә ишарәли дип саный.
Беренчедән, Җәнабел-Хак әүлия затны эш-гамәлләрдә үз иркенә куя, ул теләгән нәрсәләрне булдыра. Моңа түбәндәге хәдис-шәриф дәлил итеп китерелә: «Аллаһ Тәгаләнең чәче-башы тузган, ишекләрдән куып чыгарылган, игътибар-хөрмәт күрмәгән күпме колы бар, ул коллар берәр нәрсә өчен Аллаһ белән ант итсә, Ул бу нәрсәне чынга ашырыр» (Мөслим, «Бирр», 138/2622).
Икенчедән, бәндә ихтыярының Аллаһ ихтыярына туры килеп, бер эш-гамәлнең чынга ашырылуы.
Өченчедән, Аллаһның ихтыяри әмере белән чынга ашкан эш-гамәлләр.

һәм ахирәт гыйлеменә ия Хәзрәти Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең бөеклеген һәм Аның иң мөкәммәл урын биләвен дә ассызыклый.

Хозыр галәйһис-сәләәм кыйссасы вакыйгалар һәм күренешләрнең асылын акыл тарафыннан бары аларның сәбәпләрен аңлагач кына төшенелгәнен дә бик ачык раслый. Сәбәп-нигезләр күренмәсә, акыл гаҗиз хәлдә кала һәм хикмәтне төшенә алмый. Икенче яктан караганда, Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм шәригать алып килгән пәйгамбәр булып тора һәм бу шәригатьне тормышта кулланырга бурычлы. Хозыр галәйһис-сәләәм исә Аллаһның үзенә бирелгән ләдүнни гыйлем белән гамәл кыла.

Муса галәйһис-сәләәмнең Хозыр галәйһис-сәләәмгә каршы әйтүе шәргый чикләрне сакларга омтылышыннан килеп чыга. Чөнки күзгә күренеп торган нәрсәләрдән җаваплы Муса галәйһис-сәләәм үз заманына, үз даирәсенә хас гыйлем белән эш йөртә һәм вакыйгаларны шул гыйлем кысаларында бәяли.

Ләдүнни гыйлемгә ия Хозыр галәйһис-сәләәм исә, киләчәкне күрә белгәнлектән, Муса галәйһис-сәләәмгә язмыш белән бәйлелеге анык күзгә ташланган вакыйгаларны күрсәтә. Димәк, Хозыр галәйһис-сәләәм эш-гамәлләре һәм аңа каршы чыккан Муса галәйһис-сәләәмнең үз-үзен тотышы илаһи гыйлемдә парадокс, бер-берсенә туры килмәгән күренеш хасил итми. Хозыр галәйһис-сәләәм гадәти акыл чикләрен узып киткән бер гыйлем шартларына нигезләнеп кенә эш йөртә.

Димәк, табигатьтә акыл чикләрендә төшенеп булмый торган хикмәтләр дә бар. Ул очракта хакыйкатьне эзләгәндә, акылга гына таяну дөрес түгел. Күз билгеле бер ераклыкта гына күрә белгән, колак та билгеле бер ераклыкта гына ишетә алган кебек, акылның да вакыйгаларны һәм хакыйкатьләрне аңлауда чиге бар. Акылның ул чиген узып китүгә, аң-зиһен, һичшиксез, көчсез хәлдә кала. Бу очракта күңелнең Хак Тәгаләгә буйсынуы таләп ителә.

Имам Газали хәзрәтләре дә акыл белән илаһи серләргә тулысынча төшенеп булмаячагына инангач, акылның «аръягы»на күңел дөньясы белән күчү кирәклеген аңлый, бары шул рәвешле генә асыл хакыйкатькә ирешә алачагын белдерә.

Имам Газали «Тәһафүтүл-Фәласифә» дип аталган хезмәтендә, философларның фикерләрен кире кагып, акылның гаҗизлеге, чикләнгәнлеге турында сүз алып бара. Үзенең рухи халәтен ул түбәндәгечә тасвирлый:

«Акылымны тарттым-суздым, өзелеп-ертылып китәр дәрәҗәгә җитте һәм аның бер ноктадан соң һичшиксез гаҗизлеген, көчсезлеген тойдым. Илаһи серләрне аңлар өчен, Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең рухи бәрәкәтенә ирешүдән башка чара юк икәнен төшендем! Хак Тәгаләгә догада ялвардым. Фикерләү, булганына канәгатьләнү һәм зикер кебек рухи тәрбия ысуллары нәтиҗәсендә Рәсүлүллаһка хас күңел халәтенә һәм котылуга ирештем».

Көймәнең тишелүе, вакыйганың тышкы ягына караганда, аның хуҗаларына карата хаксызлык һәм золым була. Чынлыкта исә ярлы-ябагайның тормышын туендырып тору чарасы булган көймәнең явыз затлар тарафыннан талап алынуына комачаулый. Егетнең үтерелүе дә, беренче карашка, җинаять булып күренә; хакыйкатьтә исә изге ата-аналарының һәм хәтта үтерелгән егетнең үзенең дә ахирәт тормышын саклаудан гыйбарәт. Хәзрәти Муса белән Хозырны куган бер авылдагы инде авып яткан диварның төзекләндерелүе, беренче карашка, мантыйкка каршы килә; хаклыкта исә ике мескен ятимгә тиешле әманәтне саклау булып тора.

Бу вакыйгаларның серләре бары ләдүнни гыйлем (йөрәк гыйлеме) белән генә ачыла. Шунлыктан тәкъдир серен акыл белән генә төшенеп булмый. Чөнки тәкъдир төшенчәсен тулысынча аңлау сәләте бәндә аңының чикләреннән чыгып китә.

Бохаридә әлеге кыйсса белән бәйле мондый эчтәлектәге хәдис-шәриф бар: «*Гыймран улы Мусага Аллаһның рәхмәте булсын! Әгәр сабыр итә белсә, Хозыр аңа тагын күпме гаҗәеп хәлләрнең серләрен өйрәткән булыр иде*» (Бохари, «Әнбия», 27; Әхмәд ибне Ханбәл, V, 118).

Мәүләна куддисә сирруһ, ләдүнни гыйлемнең бер бәхет эше икәнлеген һәм аңа ирешүнең бары күңел омтылышы һәм илаһи максатка гына бәйле булуын түбәндәге мисал белән бик күркәм аңлатып бирә:

«Йосыфның йөзендә гайре табигыйлекне, үзенчәлекне күрү Ягъкубка гына хас бер сыйфат була. Йосыфның ага-энеләренә ул нурны күрү бәхете тәтеми. Туганнарының күңел дөньясы Йосыфның хикмәтен күрерлек, аңларлык дәрәҗәгә җитми».

«Күңел ризыгы – мәхәббәт. Җаннарныкы исә – ачлык».

«Ягъкубта Йосыфка тартылу сыйфаты бар. Шуңа күрә Йосыф күлмәгенең исен ул бик еractан ук сизә. Йосыфның күлмәкне алып килгән кардәше исә ул исне сизүдән мәхрүм була».

«Бик галим кешеләр бар, гыйрфан иясе булу бәхетенә ирешкәннәре юк. Гыйлемне ятлап өйрәнгәннәр, ә Аллаһның дусты була алмаганнар...»[138]

**Өч изге бәндә**

Исраил угыллары арасында изге кешеләр дә була. Әйтик, бер хәдис-шәрифтә Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм аларның өчесе турында искә ала:

*«Сездән әүвәл яшәп киткәннәрдән өч кеше юлга чыга. Төн уздыру өчен бер мәгарәгә керәләр. Шулчак таудан бер таш тәгәрәп төшеп, мәгарә авызын*

138. Бу мәсьәлә белән бәйле тулырак мәгълүмат өчен карагыз: «Имандан Ихсана ТАСАВВУФ», 341–368 б

*каплый. Бу өч кеше, хәлнең авырлыгын күреп: «Изге гамәлләребез белән дога кылудан кала, безне моннан бернәрсә дә коткара алмаячак», – ди.*

*Арадан берсе болай дип дога кыла:*

*«Аллаһым! Минем бик карт әти-әнием бар иде. Аларны ашатмыйча торып, балаларыма да, мал-туарыма да ашарга-эчәргә бирми идем. Көннәрдән беркөнне утын җыярга дип еракка киткән идем. Алар йокларга ятканчы кайта алмадым. Кичке ашларын әзерләдем, тик алар инде йоклаган иде. Аларны уятырга да, әти-әниемнән алда гаилә белән сөт эчәргә дә күңелем тартмады. Касәне кулыма тоткан көе әти-әниемнең уянганын көттем. Ниһаять, таң беленә башлады. Балалар аяк очымда ачлыктан елый иде. Шул вакыт әти-әнием уянды да сөтләрен эчтеләр.*

*Аллаһым! Әгәр бу эшне Синең ризалыгың өчен эшләгән булсам, шушы таш аркасында килеп чыккан бәлабезне бездән ерагайт!»*

*Шуннан соң таш селкенеп куя һәм аз гына тишек ачыла, ләкин ул кеше сыярлык булмый.*

*Юлчыларның икенчесе болай дип ялвара:*

*«Илаһым! Агамның бер кызы бар иде, аны һәркемнән дә көчлерәк сөйдем (бер риваятькә күрә, бер ир-ат хатын-кызны никадәр нык яратырга сәләтле булса, мин дә шулкадәр ярата идем). Аны үземнеке итәргә теләдем. Ләкин бу кыз тәкъдимемне кире какты. Берничә елдан соң, бик фәкыйрьлеккә төшкәч, миңа мөрәҗәгать итте. "Минеке булсаң, йөз дирһәм бирермен", – дидем. Ничарадан бичара ризалашты. Шуннан соң уңайлы форсат табып, аңа кагылырга җыенган вакытта, бу кыз: "Аллаһтан курык, хаксыз рәвештә кызлыгымны бозма!" – диде. Мин исә, Аллаһтан куркып, үзем бик сөйгән хатын-кызны, ул миңа үз тәнен бирергә мәҗбүр чакта булса да, калдырып киттем. Биргән акчаларымны аңа бүләк иттем.*

*Аллаһым! Әгәр бу эшне бары Синең ризалыгыңны алу өчен генә эшләгәнмен икән, без тарыган бәладән коткар!»*

*Мәгарәнең ишеге тагын бераз ачыла, тик әле һаман да чыгып китәр өчен җитми.*

*Өченче кеше исә догасында мондый вакыйганы искә ала:*

*«Аллаһым! Акча түләп, берничә хезмәткәр ялладым һәм аларга тиешле кадәр түләдем. Ләкин берсе, үзенә дигән хакны алмыйча, китеп барды. Аңа тиешле түләүне әйләнешкә керттем, шуның бәрабәренә мал күбәйде. Күпмедер вакыттан соң теге кеше яныма килде дә: "Миңа тиешлене түлә!" – диде. Мин исә: "Әнә тегендә дөя, үгез, сарык һ.б.ларны күрәсеңме, алар сиңа дигән түләү хисабына үрчеде, барысын да алып кит!" – дидем. Яллы эшче: "Әй, Аллаһның колы! Минем белән шаярма!" – диде. "Синең белән шаярмыйм,*

*ничек бар, шуны сөйлим”, – дип әйттем. Шуннан соң малларны алды да, барысын да көтүе белән алып китте. Бернәрсә дә калдырмады.*

*Илаһым! Әгәр бу эшне Синең ризалыгың өчен эшләгән булсам, без тарыган бәлане өстебездән алып ташла!»*

***(Ниһаять), таш мәгарә авызыннан шуып китә һәм бу өч кеше, мәгарәдән чыгып, юлларын дәвам итә»*** (Бохари, «Бүйуг», 98; «Иҗарә», 12; Мөслим, «Зикр», 100).

Әлеге хәдис-шәриф тасаувыфтагы «гамәл белән тәвәссүл (Аллаһка якынаю)» төшенчәсенә бер дәлил булып карала. Башка яктан караганда, хәдистә тасвирланган вакыйга Аллаһ ризалыгын тормышында алгы планга куйган затларның әҗер-савапка лаек булачагына да иң үтемле үрнәк тәшкил итә. Шуңа күрә дә бәндә үз теләк-һәвәслекләренә бирелмичә, Җәнабел-Хакның кушканнарына һәм тыйганнарына буйсынырга, ягъни Яралтучысының ризалыгын алырга омтылырга һәм Аңа тәвәккәл кылырга тиеш. Чөнки Аллаһ ризалыгы һәм Аңа буйсыну бәндәнең Раббысына мәхәббәтенең иң ахыргы җимеше булып тора.

Хак Тәгалә юлында кеше ирешә алачак иң югары дәрәҗә Аллаһның колыннан разый булуына тиң, бу исә бәндәнең Аллаһтан риза булганы өчен дә әҗер-савап дигән сүз. Сүз аяти кәримәдә:

رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ وَرَضُوا عَنْهُ

**«...Аллаһ алардан разый, алар да Аннан разыйлар…»** – дип белдерелгән изге бәндәләрнең хәл-әхвәле турында бара («әл-Бәййинә», 8).

### Муса галәйһис-сәләәмнең җәннәттәге күршесе

Риваять кылынганча, беркөнне Муса галәйһис-сәләәм Җәнабел-Хакка: «Йә, Раббы! Минем җәннәттәге күршем кем ул?» – дип мөрәҗәгать итә. Җавапта аңа: «Минем фәлән-фәлән җирдә итче булып эшләгән һәм дустым булган бер колым бар. Ләкин ул ит сәүдәсеннән кала да бик мөһим бер эш башкара, әгәр үз яныңа чакырсаң, килә алмас! Җәннәттәге күршең әнә шул итче булачак», – дип хәбәр ителә.

Хәзрәти Муса кичекмәстән ул итчене күрергә бара. Үзенең Муса Кәлимуллаһ икәнен белдермичә генә, аңа: «Мин сиңа кунак булып килдем!» – ди.

Итче моңарчы килгән бәндәләрдән аерылып торганлыгы һәрьяктан билгеле бу нурлы йөзле кунагын елмаюлы йөз белән каршылап, аны өенә алып кайта. Өенең түренә утыртып, Мусаны хөрмәтли һәм сыйлый. Аңа үз куллары белән ит пешереп, алдына куя. Ә үзе, Муса галәйһис-сәләәмгә бик мөһим бер эше барлыгын әйтеп, аны көтмичә, ашый торырга куша. Итче үзе пешергән итле ризыкның калган кисәген вак-вак кисәкләргә турый. Аннары диварга

элеп куелган тартманы ипләп кенә төшерә дә андагы бик карт, чын-чынлап кош кебек кенә булып калган бер хатынга ризыкны ашата башлый. Ашагач, аның авызын пакьләп, сөртеп ала. Аннары бу хатынны юындырып, чистарта. Аны яратып, сыйпагач, кабат ипләп кенә кире урынына кайтара. Итче боларны эшләгәндә, карчык туктаусыз догалар укый.

Хәзрәти Муса бу тартманы итченең кибетендә дә күргән була, ләкин һични сорашмый. Күргәннәренә гаҗәпләнеп, ул итчене көтә.

Бөтен эшләрен тәмамлап, Хәзрәти Муса янына килгәч, итче аның ризыкка кагылмаганын күрә дә: «И, нурлы йөзле мосафирым! Ник ашый тормадың?» – дип сорый.

Муса галәйһис-сәләәм: «Син миңа бу тартманың серен сөйләмичә торып, ашый алмам!» – ди. Шуннан соң итче бу хәлне аңлатып бирә: «И, мосафирым! Бу тартма эчендәге олы яшьтәге карчык – әнием ул. Бик картаеп, йөрерлек көче-хәле калмады. Аны карарга да башка һичкем юк. Аны ялгыз калдырган чакларымда, берәр хайван зыян салмасын, дип курыкканга, менә шулай тартмага салып, югарыга элеп куям. Кайчак үзем белән кибеткә алып барам. Күңелемнең бөтен шатлыгы, бөтен хозурлыгы аны тәрбияләп, аңа хезмәт күрсәтүемнән килә. Көнгә ике тапкыр ашатам, әнкәемә карата бөтен эшләремне яратып башкарам!»

Хәзрәти Муса: «Ә син бу эшләрне эшләгәндә, ул пышылдап сиңа ни әйтә соң?» – дип кызыксына. Итче: «Әнием шушы эшләрем өчен һәрвакыт: “Аллаһ сине җәннәттә Муса галәйһис-сәләәмнең күршесе итсен!” – дип миңа дога кыла. Бу матур догага “амин”, дим. Тик ул бөек пәйгамбәргә күрше була алырлык кыйммәткә ия гамәл кайда да, мин кайда?!» – дип җавап бирә.

Шул мизгелгә кадәр үзенең кем икәнлеген яшергән Муса галәйһис-сәләәм елмаеп җибәрә һәм аны: «Әй, изге бәндә, сөенечләр сиңа! Мин менә шул Муса булам. “Анасына хезмәт күрсәтүдә һич кимчелексез гамәл кылып, аның ризалыгына ирешеп, догасын алган ул әүлия колымны җәннәттә сиңа күрше иттем!” – дип, Аллаһ мине синең яныңа җибәрде. Шөкер ит, илаһи әҗер-савап сиңа мөбарәк булсын!» – дип сөендерә.

Күзләре сөенечле күз яшьләре белән тулган итче ихлас мәхәббәт белән Муса галәйһис-сәләәмнең кулын үбә; шатлык, шөкер һәм тынычлык хисләренә төренеп, алар ризыкларын ашый башлый.

**Муса галәйһис-сәләәмнең фазыйләтләре, килеш-килбәте һәм сыйфатлары**

Аллаһ Тәгалә аның турында болай дип искә ала:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَكُونُوا كَالَّذِينَ آذَوْا مُوسَى فَبَرَّأَهُ اللَّهُ مِمَّا قَالُوا وَكَانَ عِنْدَ اللَّهِ وَجِيهًا

**«И, иман китерүчеләр! Мусаны рәнҗеткән кешеләр кебек булмагыз. Аллаһ аны алар сөйләгән нәрсәдән аклады. Ул – Аллаһ хозурында хөрмәте (һәм дәрәҗәле урыны) булган кемсә»** («әл-Әхзәб», 69).

Муса галәйһис-сәләәм Аллаһ каршында бик хөрмәтле һәм кадерле пәйгамбәр санала. Бу менә мондый вакыйгада да күренә:

Муса галәйһис-сәләәм кардәше Һарун өчен Аллаһ катында шәфәгать сорый һәм аны үзенә ярдәмче итеп билгеләвен үтенә. Аллаһ Тәгалә догасына җавап биреп, аңа сораганын бирә һәм кардәше Һарунга пәйгамбәрлек йөкли. Бу хакта аяти кәримәдә:

وَوَهَبْنَا لَهُ مِنْ رَحْمَتِنَا أَخَاهُ هَارُونَ نَبِيًّا

**«Бер рәхмәтебез буларак, кардәше Һарунны аңа бер пәйгамбәр буларак бирдек»**, – дип хәбәр ителә («Мәрьям», 53).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез: *«Муса галәйһис-сәләәм бик оялчан, бик капланып йөри торган зат була һәм шуңа күрә аның тән тиресеннән хәтта бик кечкенә урыны да тыштан күренми…»* – дип әйткән (Бохари, «Әнбия», 28).

Габдуллаһ ибне Гомәр радыйаллаһу ганһедән тапшырылган риваятькә күрә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм нидер бүлә. Шулчакта бер адәм: «Бу бүлешү Аллаһ ризалыгы өчен башкарылмады!» – дип каршы чыга. Килеп туган хәл турында Пәйгамбәребезгә хәбәр иткәч, шулкадәр ачуы килә ки, ярсуы йөзенә чыга. Аннары: *«Мусага Аллаһның рәхмәте булсын, ул моннан да ныграк рәнҗетелә һәм сабыр итә»*, – дип белдерә (Бохари, «Әнбия», 28).

Аллаһ Тәгалә Коръәни-Кәримдә Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәмгә һәм аның кыйссасына киң урын бирә. Бик күп урында аның белән Пәйгамбәр Әфәндебезне һәм Тәүрат белән Коръәни-Кәримне янәшә телгә ала.

Муса галәйһис-сәләәмнең килеш-килбәте турында Пәйгамбәр Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисе Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмә тарафыннан риваять кылына: *«Гайсә ибне Мәрьям, Муса һәм Ибраһимне күрдем. Гайсә кызыл тәнле, бөдрә чәчле һәм киң күкрәкле иде. Муса исә эре гәүдәле һәм туры чәчле иде»*.

Әсхабе кирам Ибраһим галәйһис-сәләәм турында сорагач, галәйһис-саләтү вәс-сәләәм Әфәндебез, аларның үзләренә ишарәләп: *«Дусларыгызга карагыз»*, – дип әйтә (Әхмәд ибне Ханбәл, «Мүснәд», I, 296).

Муса галәйһис-сәләәмнең үлеме хакында төрле риваятьләр бар. Ләкин иң атаклы риваятькә күрә, ул йөз егерме яшьтә вафат була һәм Иерусалим тирәсендә җирләнә.

Галәйһис-сәләәм!..

# БҮГЕНГЕ ИУДАИЗМ

### Иудаизмда тәңрене танып белү

Яһүдиләр бер Аллага гына ышанулары турында сөйлиләр. Ләкин бүгенге көндәге Тәүратның кайбер бүлекләренә күз салсак, Аллаһка ышануларында шактый күп антропоморфик үзенчәлекләрне күрә алабыз. Антропоморфизм – тәңрене кешегә яки яратылган кайбер мәхлукларга охшатып тасвирлаган инану төре. Бу инану аң һәм хыял чикләрен ашкан, ягъни бөек һәм ирекле булган Аллаһка ышанудан бик ерак.

Иудаизмда Аллаһның исемнәре Яһвә (Яхова) һәм Элохим дип төрле рәвештә атала. Бүгенге Тәүратта Яһвә исеме очраган урыннарга галимнәр «яхвист текстлары» диләр. Безнең эрага кадәр X гасырда язылган, дип фаразланган әлеге текстларда кешегә хас булган хис-кичерешле антропоморфик бер тәңре сурәтләнүе ап-ачык күренә. Элохим исеме очраган текстлар «элохист текстлары» дип атала. Безнең эрага кадәр VII гасырда язылган, дип сөйләнгән бу текстлар, соңрак башкалары белән берләштерелеп, бүгенге Тәүрат хәленә китерелгән.

Яһвә яһүдиләр өчен шул ук вакытта милли тәңре дә. Имеш, Раббы яһүди милләтен сайлап алган, рухи мәхәббәтен һәм игътибарын бары тик аларга гына багышлаган. Башка мәхлукларны һәм кешеләрне дә яраткан. Ләкин аларның дәрәҗәсе яһүдиләрнеке кебек кадерле түгел. Дөньяда хуҗа кавем – яһүдиләр. Шушы инануга нигезләнгәнгә күрә, иудаизм бөтен җиһанга исәпләнгән дөнья тәртибен корырлык һәм бөтен кешелекне кочакларлык дин булудан ерак тора.

Тәңренең антропоморфик (кешегә хас) сыйфатлар белән тәкъдим ителүе соңрак дәвер яһүди галимнәре фикеренә нигезләнеп аңлатылган, боларның барысы да образлы рәвештә тасвирланган. Алар әйтүенә караганда, тәңре кешеләр аңлый ала торган телдә сөйләшкән. Шуңа күрә бу төр гыйбарәләрнең антропоморфик хосусиятләрне аңлатуы гаять табигый хәлдер. Әмма Тәүратта Раббыны кешегә хас сыйфатлар белән тасвирлаган гыйбарәләр бу фикерне ялганга чыгарырлык дәрәҗәдә күп. Боларны раслаган берничә мисал китерик.

Тәңре, кешеләрнең бик күп яманлыклар кылганын күргәч, аларны яратуына бик борчыла һәм аларны туфан белән һәлак итә. Бу юлы инде кешеләрне һәлак итүенә нык газаплана һәм бүтән бу ысул белән дөньяны һәлак итмәячәге турында сөйли («Яратылыш», 6/5–7, 8/21–22). Шул рәвешле тәңрегә ап-ачык хаталану һәм борчылу хисе кебек кешегә хас сыйфатлар кушыла.

Исраил угыллары Раббыларына каршы баш күтәреп чыккан чакта, тәңре аларны бөтенләй һәлак итәргә карар кыла. Ләкин ике арага пәйгамбәрләр килеп кереп: «Һәлак итмә!» – дип, тәңрене бу карарыннан кире кайтарырга тырышалар. Нәтиҗәдә, тәңре үз карарыннан ваз кичә. Шулай итеп, ахырдан тәңренең кешеләрне һәлак итәргә булган карары аркасында бик тирән борчуга төшүе тасвирлана («Чыгыш», 37/9–12, 14; «Амос», 7/2–6).

Хәтта «Иеремия» китабында Исраил угылларының һич чиге булмаган фетнәләренә бәйле рәвештә тәңренең: «Инде кызгана-кызгана арыдым!» – дигән сүзләре китерелә («Иеремия», 15/6).

Тәүраттагы: «Тәңре дөньяны алты көндә яратты. Җиденче көнне исә ял итте», – дигән гыйбарә дә («Яратылыш», 2/3) – Аллаһка көчсезлек хас булуын раслый торган бер мисал. Югыйсә, ял итү, кызгану һәм ару-талчыгу, кешеләргә һәм мәхлукларга хас сыйфатлар булып, көчсезлекне һәм гаҗизлеккә төшүне белдерә.

Тагын да ныграк гаҗәпләндергәне шул: вәхи нәтиҗәсендә иңдерелгән китапта һич урын алырга тиеш булмаган менә мондый җөмләләр дә китерелә Тәүратта: «Аллаһның угыллары Адәм кызларының матур булуларын күрделәр һәм барлык сайлаганнарына да өйләнделәр» («Яратылыш», 6/2).

Тәүратның «Яратылыш» бүлегендә тәңренең ике фәрештә белән бергә, кеше сурәтенә кереп, Ибраһим янына килүе, анда кунак булуы һәм алар белән бергә ашап-эчүе, аякларын юып ял итүе турында сөйләнә. Соңрак тәңре фәрештәләрен, Лут кавемен һәлак итәр өчен, Содом һәм Гоморрага җибәрә. Фәкать моны Ибраһимгә аңлату мәсьәләсендә икеләнә һәм ахырдан сөйләп бирә. Моңа каршы Ибраһим, Лут кавемендә яхшы кешеләр дә булу сәбәпле, бу кавемне һәлак итмәсен өчен, Раббысы белән озак вакыт сатулаша («Яратылыш», 18/1–15).

Тәүратта Ягъкуб галәйһис-сәләамнең Яһвә тәңре белән булган көрәше дә сурәтләнә. Бу да шактый игътибарга лаек бер вакыйга. Гаилә әгъзалары белән бергә агасы яныннан Кәнан иленә кайтып килгәндә, Хәзрәти Ягъкуб чүлдә бер кеше белән очрашып, таң сызыгы агара башлаганчы, шуның белән көрәшә. Ягъкуб галәйһис-сәләам: «Туктат моны, китик!» – дигәч тә, аның белән көрәшүче кеше туктамый һәм соңрак Ягъкуб галәйһис-сәләамгә: «Моннан соң сиңа Ягъкуб түгел, Исраил (яһүди теленнән – тәңре белән көрәшкән), диярләр. Чөнки син Аллаһ һәм кешеләр белән көрәштә күп көч түгеп җиңдең!» – ди («Яратылыш», 32/22–32).

Тәүратта аңлатылганча, бу көрәш вакытында Ягъкубның бот сөяге имгәнә. Шуңа күрә яһүдиләр хәтта бүген дә бот сөягендәге сеңерләрне ашамыйлар.

Тәүраттагы: «Тәңре, гадәти бер кеше сурәтенә кереп, Ягъкуб галәйһис-сәләам белән көрәште», – дигән җөмлә антропоморфик гакыйдәгә ап-ачык

мисал булып тора. Бу исә – тәүхидтән бөтенләй дә ерак нәрсә, камил сыйфатлардан мәхрүм һәм кимчелекле сыйфатларга ия Аллаһка ышануны белдерә.

Моңа охшаш инану (миф) индуизмга да хас. Анда да тәңре, берәр кеше яки хайван кыяфәтенә кереп, җир йөзенә иңә. Бу күренеш индуизмда «тәңренең аватарасы» дигән сүз белән белдерелә.

Яһүди дин галимнәре Иске Гаһедтә очрый торган мондый кыйссаларны төрлечә тәфсир кыла, төрлечә аңлатырга тырыша. Нәтиҗәдә, бу вакыйга Тәүрат тәфсирләрендә: «Ягъкуб белән көрәшкән ул кеше тәңре түгел, тәңре рәвешендә күренгән бер фәрештә булган», – дип аңлатыла. Хәтта шулай булса да, бу юлы бер мәхлукның тәңре кыяфәтенә керә алу фикере калкып чыга, ә монысы исә тәүхид күзлегеннән аңлату һич мөмкин түгел.

Тәүраттагы көрәш вакыйгасыннан соң: «(Муса): “Тәңрене каршымда күрдем һәм җаным исән калды!” – дип әйтте», – дигән җөмлә исә («Яратылыш», 32/30) моңа төшенергә мөмкин булмаслыкны белдерә. Җөмлә, асылда, гаять ачык һәм аңлаешлы. Соңрак бу вакыйганың Тәүратта ни өчен урын алуы, хикмәт һәм сәбәбенең нидә булуы да тулаем ачыкланмый. Һәр вакыйганың барлыкка килүенә ниндидер сәбәпләр нигез булып тора, бу вакыйга белән бәйле һичбер сәбәп тә күрсәтелми.

Югарыда сөйләнгәнчә, Тәүратта Аллаһ Тәгаләнең «Сөбхан» булуы, ягъни кешегә хас һәртөрле сыйфатлардан азат, камил сыйфатлары белән аерылып торган бер Раббы булуы турында хакыйкатькә каршы килеп, Аңа кешегә хас гаҗизлек сыйфаты тагыла. Кешеләр тарафыннан үзгәртелгән Тәүратта бу мәсьәләгә кагылышлы башка мисаллар да очрый:

«Һәм Муса кавеме әһелләреннән һәркайсының үзләренең күчмә чатыры ишеге төбендә елап утыруын ишетте һәм Раббысының моңа бик нык ачуы кабарды; һәм Муса да моннан канәгатьсез булды. Һәм Муса Раббысына әйтте: «Ни өчен син мине – Үз колыңны газаплыйсың? Ни өчен мин синең күз алдыңда шәфкать казанмадым һәм нигә син бөтен халыкның авырлыгын минем өстемә йөкләдең? Бу халыкны үземнең карынымда мин йөрттемме әллә, аны мин тудырдыммы әллә?! Ни өчен Син миңа: “Сабыйны күтәреп йөрткән бала караучы сыман, аларны күтәреп йөрт – аталарына бирергә ант иткән җиргә алып бар!” – дип әйттең? Бу кадәр халыкны ашату өчен, кайдан ит алыйм?! Алар бит: “Безгә ашарга ит бир!” – дип, миннән елап сорыйлар. Шушы халыкны мин берүзем генә кайгырта алмыйм – минем өчен бу гаять авыр йөк. Әгәр миңа шундый мөнәсәбәттә икәнсең, мине үтерүең яхшырак булыр – синең күз алдыңда шәфкать казанган булсам, нинди бәлагә таруымны күрмәм ул чакта!» («Саннар», 11/4–6, 10–15).

Җәнабел-Хакка золым сыйфатын таккан бу гыйбарәләр Муса галәйһис-сәләамнең, Раббысына дога кылып, ялварасы урында, Аңа баш күтәреп,

үз-үзен буйсынмас гыйсьянчы итеп тотуын күрсәтә. Бу хәл ничек изге китапта шулай бәян кылына ала?

Тәүратта Аллаһка иман төшенчәсенә каршы килгән тагын менә мондый бер вакыйга турында сөйләнә:

«Көндез күләгәдә җәннәт бакчаларында йөргәндә, Раббы Адәм белән Хәүваны эзли. Алар агачлар артына качкан була. Тәңре аларны күрмичә: "Кайда сез?!" – дип, Хәзрәти Адәмгә дәшә. Адәм: "Бакчада тавышыңны ишетүгә курыктым. Чөнки ялангач идем, шуңа күрә яшерендем", – ди» («Яратылыш», 3/8–10).

Барлык бу мәсьәләләр ни рәвешле генә бәян ителсә дә, язылганнарның бозып тапшырылуы үзеннән-үзе аңлашыла.

Бүген кайбер галимнәр Тәүрат кыйссаларындагы антропоморфик тәңрегә инануның арткы планында Борынгы Мисыр һәм Вавилонда булган мәҗүсиләр һәм мифологик тәңрегә ышануларының йогынтысы сизелүен һәм бу ышануларның яһүдиләргә дә, Тәүратны язучыларга да тәэсир иткәнен белдерә.

**Тәүрат**

Бүгенге Тәүрат – гамәлдәге Бибилиянең беренче биш бүлеген тәшкил иткән өлеше. Яһүдиләрнең Изге Язмасының иң әһәмиятле бүлеге булып тора. «Яратылыш», «Чыгыш», «Левиләр», «Саннар» һәм «Канун» китапларыннан гыйбарәт.

Бу китапларда яратылыштан алып Хәзрәти Мусаның вафатына кадәр булган дәверләр тасвирлана. Аларда, шулай ук, дини хөкемнәр дә китерелә. Ләкин «Канун» китабының соңгы бабында Хәзрәти Мусаның вафаты, дәфен кылынуы һәм кавеменең матәме сурәтләнә. Хәлбуки Тәүрат Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм исән чакта ук иңдерелгән. Вакыйга булганчыга кадәр аның турында ничек язып була соң? Яһүдиләр моңа да аңлатма бирәләр. Бер өлеше: «Хәзрәти Мусага боларны Тәңре белдергән. Ә ул үлгәнче боларны Тәүратка язып калдырган», – дисә, икенчеләре: «Хәзрәти Мусадан соң Исраил угыллары кичергән вакыйгаларны Юша язып куйган», – диләр.

Бу бүлектә Хәзрәти Мусаны җирләргә әзерләү һәм кәфенләү йолаларының тасвирлануы Тәүратка кеше кулы катышуына ап-ачык дәлил булып тора.

Тәүраттан тыш яһүдиләрнең Изге Язмасында икенче бүлекне «Пәйгамбәрләр» (Невиим) китабы тәшкил итә. Ул үзе егерме бер китаптан тупланган. Изге язманың өченче бүлеге «Кетувим» (язмалар, китаплар) дип атала һәм унөч китапны берләштерә. Ягъни яһүдиләрнең Изге Язмасы Тәүратта – 5, «Пәйгамбәрләр»дә – 21, «Язмалар»да 13 китаптан кушылган 39 бүлектән гыйбарәт. Бу тупланманы яһүдиләр «шәригать» мәгънәсен белдергән «Танака»

(Т=Тәүрат, Н=Невиим, К=Кетувим) исеме белән атый, ә христианнар «Иске Гаһед» дип йөртә.

Ләкин яһүдиләр бу тупланмадагы китаплар санын егерме дүрт, яки иврит әлифбасындагы хәрефләр санынча – егерме ике, ә христианнар исә утыз тугыз итеп күрсәтә. Эчтәлеге бер үк булып, бүленешнең төрлелегендә аерма шунда: христианнар һәрбер китапны мөстәкыйль аерым бер әсәр буларак кабул итә, ә яһүдиләр берничә китапны берләштереп саный.

Тәүратта соңгы бүлекләрнең Хәзрәти Мусадан соң килгән пәйгамбәрләр белән бергә өстәлгән бүлекләр булуы белдерелә. Мәсәлән, Муса галәйһис-сәләәмнән соң Юша (Иешуа) килә һәм «Юша китабы» (Иисус Навин китабы), аннары «Патшалык китаплары» һ.б. өстәлә, шулай дәвам итеп, барлыгы 39 китап барлыкка килә.

Хәзрәти Мусага нисбәтлелеге турында сөйләнгән Тәүраттагы Иске Гаһед текстларының тәмамланып, рәсми кабул һәм игълан ителүе безнең эраның 90–100 нче елларында (ягъни Хәзрәти Мусадан соң якынча 1300 ел узгач) була. Иске Гаһед, Яһүди мәҗлесендә (Явне академиясендә) берничә нөсхә арасыннан сайлап алынып, билгеле бер стандарт рәвешенә китерелә.

**Талмуд**

Яһүдиләр, язулы Тәүратка өстәп, Аллаһ тарафыннан Хәзрәти Мусага иңдерелгән сүзле бер вәхи булуы турында сөйлиләр һәм аны Талмуд дип атыйлар. Яһүдиләр Талмудны Тәүрат белән бер үк дәрәҗәдә күрә һәм аны кабул итмәгән кешене чын яһүди дип санамыйлар.

Талмуд – Хәзрәти Мусаның Тәүрат текстларына аңлатмаларыннан гыйбарәт тәфсир булып тора. Башлангыч чорда бу тәфсирләр телдән сөйләнеп килгән. Соңгыраклары кәгазьгә язылган. Боларын «Мишна» дип йөртәләр. Мишна дини әмерләрне куллану мәсьәләләрендәге аңлатмаларны колачлый. Палестина һәм Вавилонда булган яһүди дин мәктәпләрендә Мишна өйрәнелә. Нәтиҗәдә, Талмуд барлыкка килә. Бүген ике төрле Талмуд – Иерусалим һәм Вавилон Талмуды бар. Алар безнең эраның IV һәм V гасырларында языла.

Мишна – «кабат» дигән сүз, Талмуд исә «тәгълим» (гыйлем бирү) дигәнне аңлата. Бу күзлектән караганда, Талмуд Тәүраттагы хөкемнәрнең аңлатмаларын тәшкил иткән тәфсир һәм күрсәтмәләр җыентыгы була. Чөнки Тәүраттагы хөкемнәр гомуми. Мәсәлән, тәңре: «Җиденче елда басуга берни дә чәчмәссең!» яисә: «Шимбә көнне эш эшләмәссең!» – ди. Ләкин бу әмерләргә аңлатма юк, анысын Талмуд бирә. Ләкин Талмудның ничек барлыкка килүенә игътибар итсәк, кеше ихтыяҗларының, теләк-ниятләренең илаһи гыйбарәләрдән өстенрәк булуын ап-ачык күрәбез.

Талмудта төп фикер – яһүдиләрнең өстен халык булуына дәгъва кылу. «Ун әмер» бары тик яһүдиләр арасында гына гамәлдә саналып, яһүди булмаганнар өчен аларның һичнинди мәгънәсе юк һәм бу хөкемнәр бернинди җаваплылык та йөкләми дип санала.

Нәтиҗәдә, яһүдиләрнең изге китапларындагы төп фикер тәңренең өстен кавем итеп Исраил угылларын сайлап алуына нигезләнә. Шул сәбәпле, Иске Гаһедтә тарихи бәян җәмгыятькә тапшырылырга тиешле хәбәрдән өстен чыгарыла, беренче планга куела. Вакыйгаларның тәфсилләп тасвирлануы, ялыктыргыч һәм озын нәсел исемлекләре – моның ачык мисалы. Кыскасы, яһүдиләрнең изге китабында Исраил угылларының тарихы һәм аларның тәңре белән мөнәсәбәтләре язылган. Бу күзлектән караганда, иудаизм – бөтен кешелек дөньясын сәгадәткә илтүдән мәхрүм бер кавем дине булып, бөтендөнья дине дәрәҗәсенә дәгъва кылудан ерак тора.

**Пәйгамбәрләрне кабул итү**

Иудаизмда Хәзрәти Ибраһимнән башлап, барлыгы кырык сигез пәйгамбәр бар. Аннан да әүвәлрәк чорга кадәр пәйгамбәрләр җибәрелмәгән булган. Бу кырык сигез пәйгамбәрнең уналтысы – кануни, ягъни Изге Китапта үзләренә язу насыйп ителгән пәйгамбәрләр. Җидесе – хатын-кыз пәйгамбәр.

Тәүратта әйтелгәнчә, пәйгамбәрләр ике төрле була: ялган һәм чын пәйгамбәрләр. Бу кырык сигез пәйгамбәрдән кала, башкалары – ялган. Алар пәйгамбәр дип кабул ителми.

Чын пәйгамбәрләр:

1. Кешеләрне Аллаһка кол булырга (гыйбадәт кылырга) өндәргә һәм Аллаһтан башка илаһларга иярмәскә тиешләр («Иеремия», 14/14, 23/21, 32).

2. Киләчәккә кагылышлы хәбәрләр җиткерергә тиеш һәм аларның сөйләгәннәренең тормышка ашуы мөһим («Канун», 18/20–22).

Бу ике шарттан кала, ислам динендәге кебек, пәйгамбәрләр өчен ваҗиб булган биш сыйфат юк. Бәни Исраил динендә пәйгамбәрләр алдалый, хәйлә кора, ялган сөйли ала, зиначы һәм җәберләүче, бары тик үзе турында гына уйлый торган эгоист холыклы булырга мөмкин һ.б.

Хәтта яһүдиләрнең пәйгамбәрләре турында бәян итү рәвеше дә үзләре билгеләгән бу ике шартка туры килми. Мәсәлән, үзгәртелгән Тәүратта Һарун пәйгамбәр, алтын бозау ясап, шуңа табынырга кушуда гаепләнә («Чыгыш», 32/1-5, 24, 35). Яһүдиләр Һарун галәйһис-сәләәмне пәйгамбәр дип түгел, ә Хәзрәти Мусаның ярдәмчесе һәм күрәзәче, кам буларак кабул итәләр. Алар пот вакыйгасын «Һарун галәйһис-сәләәм потны кавеменең басымы астында ясады», – диеп аңлатсалар да, чынлыкта исә, бу хәл пәйгамбәрлек вазифасының асылына берничек тә туры килә алмый. Чөнки пәйгамбәрләр илаһи яклау

астында. Коръәни-Кәрим исә алтын бозау турында яла-ялганны катгый кире кагып, вакыйганың чын дөресен хәбәр итә. Коръәнгә күрә, Хәзрәти Һарун – потны ясаучы түгел, ә киресенчә, бозау потын ясауга каршы төшәргә тырышкан, хәтта шул сәбәпле бер төркем потпәрәст Исраил угыллары тарафыннан җәзалап үтерелү куркынычы янаган пәйгамбәр ул.

Иудаизмда Аллаһка ышану төшенчәсенең генә түгел, пәйгамбәрләргә ышануның да кайбер үзенчәлекләре бар. Пәйгамбәрлек төшенчәсе иудаизмда бик күп каршылыклы хасиятләр белән тулы. Нәтиҗәдә, Хәзрәти Адәм, Хәзрәти Идрис, Хәзрәти Нух һәм башкалар пәйгамбәр буларак кабул ителми. Ләкин аларда түбәнрәк дәрәҗәдә булган нәбилек вазифасы барыбер бар. Чөнки Иске Гаһеднең «Яратылыш» китабында тәңренең боларга вакыт-вакыт вәхи иңдерүе турында белдерелә. Хәзрәти Давыт һәм Хәзрәти Сөләйманның патша буларак кабул ителүләренә карамастан, тәңре белән вәхи аша элемтәдә булулары хакында да сөйләнә.

Яһүдиләр кайбер пәйгамбәрләрне сәер һәм бөтенләй кабул ителә алмастай сыйфатлар белән сурәтлиләр. Алар фикеренчә:

а) Хәзрәти Нух – туфаннан соң йөзем үстереп, шәраб ясау белән шөгыльләнгән һәм хәмер эчүче сәрхуш була. Беркөнне шулкадәр күп эчеп, үз-үзен белештерми башларлык дәрәҗәгә җитә һәм чатыры эчендә йоклап кала. Шулчак кече угылы Хам килеп керә һәм атасының ялангач булуын күрә. Бу хакта абыйлары Сам белән Яфәскә барып сөйли. Алар килеп аталарының өстенә каплый. Нух, айныгач, кече угылының аңа карата яманлык кылуын аңлый... Тик шуннан соң ул бу эшкә катнашы булган угылын түгел, ә угылының угылын, ягъни оныгы Кәнанны ләгънәтли. Шул сәбәпле Кәнан исеме иудаизмда иң начар исемнәрнең берсе буларак кабул ителә («Яратылыш», 9/20–29).

б) Тәүратка күрә, Хәзрәти Лут кызлары белән зина кылган. Содом һәм Гоморра шәһәрләре һәлак ителгәннән соң, Хәзрәти Лут ике кызы белән котылып кала. Алар бер мәгарәгә кереп сыена. Хәзрәти Лут йокыга китә. Кызлары: «Илебездә нәселне дәвам итү өчен кияүгә чыгарлык ир кеше калмады. Атабызга шәраб эчертик!..» – диләр һәм аталары белән зина кылалар («Яратылыш», 19/30–36).

в) Атасының догасын алу өчен, Хәзрәти Ягъкуб игезәк туганы Гыйсне алдалый («Яратылыш», 27 нче баб). Шулай ук Хәзрәти Ягъкубның, каенатасы белән килешү төзегәндә, хәйлә белән көтүдән иң яхшы сарыкларны үзенә аерып алуы турында сөйләнә («Яратылыш», 30/32–42, 31/7–16).

г) Хәзрәти Давыт – бик күп хатыны булган патша. Шуңа да карамастан, гаскәр башлыгы Урйаның хатынын күргәч, аңа күзе төшә һәм аның белән зина кыла. Ахырдан Урйаны хәйлә белән сугышка җибәреп, үтертә. Давытның бу гамәленә җәза буларак, аның беренче баласы үлә. Икенче баласы – Хәзрәти

Сөләйман. Яһүдиләрнең изге китабында бу гамәлләр турында сөйләнә һәм Хәзрәти Давыт турында нибары «Раббысы алдында яман булганны кылды», дип кенә искә алына (II Патшалык китабы, 11/2–12/22).

д) Хәзрәти Сөләйманның хатыны берәү генә була. Ләкин ул да гомеренең соңгы көннәрендә потпәрәст хатыннарга ияреп, потларга табына. Шулай итеп Хәзрәти Сөләйман турында да: «Раббысы алдында яман булганны кылды», – диелә (I Патшалык, 11/1–7).

Болардан тыш кайбер пәйгамбәрләрнең якыннары турында да әдәпсез нәрсәләр сөйләнә. Мәсәлән, Хәзрәти Ягъкуб угылы Яһуданың килене белән зина кылуы турында әйтелә («Яратылыш», 38/12–26). Ягъкубның икенче угылы Рубенның исә атасының җариясе белән якын мөнәсәбәттә булуы хакында бәян ителә («Яратылыш», 35/22). Шулай ук Хәзрәти Давытның бер угылы үги кыз кардәше белән (II Патшалык китабы, 13 нче баб), икенче угылы исә атасының җариясе белән зина кыла (II Патшалык китабы, 16/15, 20–23).

Әлбәттә, боларның барысы да – яһүдиләрнең пычрак ялганнары. Алар бу ялганнар белән генә чикләнмәгән, күп пәйгамбәрләрне үтергәннәр дә. Әйтик, Хәзрәти Зәкәрия белән аның улы Хәзрәти Яхъя – яһүдиләр тарафыннан үтерелгән ике мәзлум пәйгамбәр.

Яһүдиләрнең бу хәле турында Коръәни-Кәрим мондый аңлатма бирә:

فَبِمَا نَقْضِهِمْ مِيثَاقَهُمْ وَكُفْرِهِمْ بِاٰيَاتِ اللّٰهِ وَقَتْلِهِمُ الْاَنْبِيَٓاءَ بِغَيْرِ حَقٍّ
وَقَوْلِهِمْ قُلُوبُنَا غُلْفٌ بَلْ طَبَعَ اللّٰهُ عَلَيْهَا بِكُفْرِهِمْ فَلَا يُؤْمِنُونَ اِلَّا قَل۪يلًا

**«Вәгъдәләрен бозганнары, Аллаһның аятьләрен инкяр иткәннәре, нахакка пәйгамбәрләрне үтергәннәре һәм “Безнең күңелләребез пәрдәләнгән”, дигәннәре өчен (аларны ләгънәтләдек). (Аларның күңелләре пәрдәләнмәгән). Дөреслектә, Аллаһ, көферлекләре сәбәпле, аларга мөһер сукты. Бик азларыннан тыш, алар иман китермиләр»** («ән-Ниса», 155).

Аллаһ Тәгалә «Фатиха» сүрәсендә дә **«әл-мәгъдуби галәйһим (илаһи газапка тарыганнар)»** дип, яһүдиләр турында искә ала.

### Ахирәт төшенчәсе

Тәүратта ахирәт белән бәйле анык мәгълүмат юк. Соңгырак нөсхәләрдә гөнаһ ияләренең җәһәннәмгә китәчәге, дин кушканнарны үтәүче кешеләрнең җәннәткә керәчәге турында әйтелә. Ләкин яһүдиләр тарихына күз салсак, башлангыч чорларда ахирәт турында төшенчәне очрату мөмкин түгел диярлек. Тәүратта үлүчеләр турында: «Якты көннәрдән туеп, аталары белән бергә йокладылар», – дигән гыйбарә кулланыла («Яратылыш», 47/30; «Канун», 31/16).

Соңрак дәвердә Бәни Исраил арасында «Ә үлүчеләргә ни була?» дигән мәсьәләдә бәхәс туа. Һәм үлүчеләрнең «Шәол» дип аталган мәетләр иленә китүе турында фикер урнаша.

Иудаизмда үлемнән соң терелү, әҗер-савап һәм җәза турында беренче тапкыр «Данил» (Даниил) 12/2 китабында ачык һәм аңлаешлы хәбәр ителә. Данил (б.э.к. 586–538 нче еллар) Вавилонда вавилонлыларда әсирлектә яши.

Иудаизмда ахирәт белән бәйле фикерләр күбрәк Талмудта урын алган. Аларга ярашлы рәвештә, Бәни Исраил кешеләре мәңгегә җәннәттә калачак. Гөнаһлы Исраил угыллары исә җәһәннәмдә нибары унике ай тотылачак, соңыннан алар да җәннәткә керәчәкләр.

Яһүди булмаганнарның исә барысы да җәһәннәмгә ташланачак һәм мәңгелек газапка тотылачак, чөнки иудаизм күзлегеннән караганда, яһүди булмаганнарның барысы да потка табынучы мәҗүсиләр санала («Рош ха-Шана», 17а).

***Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм***




ХӘЗРӘТИ
ДАВЫТ
галәйһиссәләм

***Зикерләре белән тауларны, ташларны һәм кыргый хайваннарны әсәрләндергән***

# ХӘЗРӘТИ ДАВЫТ

***галәйһис-сәләәм***

Хәзрәти Давыт (Давыт, Дауд) галәйһис-сәләәм Иерусалимдә туа һәм, фаразлар буенча, 100 яшьләр тирәсендә вафат була. Нәсел шәҗәрәсе Яһуда ибне Ягъкуб ибне Исхак ибне Ибраһимгә тоташа. Давытка пәйгамбәрлек тә, хөкемдарлык та бирелә. Тарихчылар фикеренчә, ул якынча б.э. кадәр 1015–975 еллар арасында патшалык итә.

Коръәни-Кәримдә Давыт галәйһис-сәләәмнең исеме 16 урында искә алына. Аңа иврит телендә Зәбур иңдерелә.

**Талут, Җалут һәм табут**

Муса галәйһис-сәләәмнән соң килгән Бәни Исраил пәйгамбәрләре Тәүрат кушканча гамәл кыла. Тик яһүдиләр, үзләрен ияртеп баручы пәйгамбәр булмаган вакытта, кечкенә генә форсат табуга, шундук китапны читкә этәреп, анда язылганнарны үз теләк-омтылышларына күрә аңлата башлыйлар. Шул рәвешле игътикад һәм әхлаклары бозыла, ә яңа пәйгамбәр килгәч, янә төзәләләр, тик соңыннан кабат бозыклыкка тартылалар.

Ул чорларда Мисыр һәм Димәшкъ арасында амалика кавеме гомер кичерә. Аның белән Җалут исемле бик көчле башлык идарә итә. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Җалутны Исраил угыллары өстенә бер бәла итеп җибәрә. Исраил угылларын җиңеп, Җалут аларның балаларын һәм хатын-кызларын әсирлеккә төшерә.

Бәни Исраил кавеме карамагында Муса галәйһис-сәләәм заманыннан бирле сакланып килгән, эченә шактый изге ядкярләр салынган кыйммәтле сандык була. Бу сандыкны кулга төшергән Җалут, кавемне кимсетергә тырышып, аны пычракка ташлый. Әлеге сандык Коръәни-Кәримдә «табут» дип телгә алына. Йортсыз, мал-мөлкәтсез, дәүләтсез калган Исраил угылларының тынычлыгы югала. Алар табутны кулдан ычкындырганлыкларына бик кайгыра. Хәзер бөтен максат-ниятләре шул табутны кире кайтару тирәсендә була.

Ул вакытларда араларында, риваятькә күрә, Ишмоил исемле бер пәйгамбәр яши. Яһүдиләр аннан үзләрен коткарачак бер хөкемдар сорыйлар. Ишмоил галәйһис-сәләәм, дога кылып, Аллаһка ялвара. Хак Тәгалә, «Талут» исемле бер кешене патша итеп билгеләргә кушып, вәхи иңдерә. Ләкин яһүдиләрнең бер өлеше, Талутны хөкемдар итеп куярга теләмичә, илаһи әмергә

каршы чыга: «Талут хөкемдар нәселеннән түгел!» – дип белдерә алар. Чөнки ул вакытка кадәр Исраил угылларына җибәрелгән пәйгамбәрләр – Лави ибне Ягъкуб; хөкемдарлар исә Яһуда ибне Ягъкуб нәселеннән чыккан була. Талут исә бу ике нәселнең һичкайсына карамый.

Коръәни-Кәримдә бу мәсьәлә түбәндәгечә бәян кылына:

أَلَمْ تَرَ إِلَى الْمَلَإِ مِنْ بَنِي إِسْرَائِيلَ مِنْ بَعْدِ مُوسَى إِذْ قَالُواْ لِنَبِيٍّ لَّهُمُ ابْعَثْ لَنَا مَلِكًا نُّقَاتِلْ فِي سَبِيلِ اللَّهِ قَالَ هَلْ عَسَيْتُمْ إِن كُتِبَ عَلَيْكُمُ الْقِتَالُ أَلَّا تُقَاتِلُواْ قَالُواْ وَمَا لَنَا أَلَّا نُقَاتِلَ فِي سَبِيلِ اللَّهِ وَقَدْ أُخْرِجْنَا مِنْ دِيَارِنَا وَأَبْنَآئِنَا فَلَمَّا كُتِبَ عَلَيْهِمُ الْقِتَالُ تَوَلَّوْاْ إِلَّا قَلِيلًا مِّنْهُمْ وَاللَّهُ عَلِيمٌ بِالظَّالِمِينَ وَقَالَ لَهُمْ نَبِيُّهُمْ إِنَّ اللَّهَ قَدْ بَعَثَ لَكُمْ طَالُوتَ مَلِكًا قَالُوَاْ أَنَّى يَكُونُ لَهُ الْمُلْكُ عَلَيْنَا وَنَحْنُ أَحَقُّ بِالْمُلْكِ مِنْهُ وَلَمْ يُؤْتَ سَعَةً مِّنَ الْمَالِ قَالَ إِنَّ اللَّهَ اصْطَفَاهُ عَلَيْكُمْ وَزَادَهُ بَسْطَةً فِي الْعِلْمِ وَالْجِسْمِ وَاللَّهُ يُؤْتِي مُلْكَهُ مَنْ يَشَاء وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ

**«Мусадан соң Исраил улларыннан булган дәрәҗәле кешеләрне күрмәдеңме? Менә алар үз пәйгамбәрләренә: “Безгә бер хөкемдар билгелә дә (аның җитәкчелегендә) Аллаһ юлында сугышыйк!” – дигәннәр иде. Ул (Пәйгамбәр): “Әгәр сезгә сугыш язылып, сез сугышка чыкмый калсагыз?” – дигән иде. Алар: “Йортларыбыздан һәм улларыбыздан куылгач, нишләп безгә Аллаһ юлында сугышмаска?!” – дигәннәр иде. Сугыш язылгач исә, араларыннан бик азларыннан тыш, алар баш тарткан (һәм качкан) иде. Аллаһ – залимнәрне (яхшы) Белүче»** («әл-Бәкара», 246).

**«Пәйгамбәрләре аларга: “Һичшиксез, Аллаһ сезгә Талутны хөкемдар итеп җибәрде!” – дигән иде. (Шуннан соң) алар: “Хакимлек итәргә аңардан без лаеклырак була торып һәм (өстәвенә) аның мал-мөлкәте (байлык ягыннан мөмкинлекләре киң) булмаган хәлдә, ничек инде ул безнең өстән патша була алсын?” – дигән иделәр. Ул (Пәйгамбәр): “Һичшиксез, Аллаһ аны сезнең өчен сайлады, аңа гыйлемне һәм гәүдәне артыграк бирде. Аллаһ хакимлеген теләгәненә бирер. Аллаһ – чиксез Мәрхәмәт иясе, Белүче”, – дигән иде»** («әл-Бәкара», 247).

Исраил угылларының аксөякләре фикеренчә, хакимият зур байлыклар һәм зур акчаларга ия затлар кулында булырга тиеш. Югыйсә, мондый фикер җәмгыять мәнфәгатенә һәм гаделлек принцибына каршы килә, чөнки идарә эшенең байлар түгел, ә моңа лаеклы затлар тарафыннан алып барылуы зарур. Бу исә ул кешенең рухи көче, белем-тәҗрибәсе белән беррәттән аның көч-кыюлыгына да бәйле.

Фәхреддин Разый аңлатуынча, Ишмоил галәйһис-сәләәм, Исраил угыллары тәкъдимен түбәндәге дүрт сәбәп аркасында кире кага:

1. Талутны хөкемдар итеп Аллаһ Җәллә Җәләлүһү сайлый.

2. Хөкемдарларда ике сыйфат булуы мөһим:

а) Сәясәт белемен (идарә итү гыйлемен) белүе;

б). Бәдәне һәм рухы куәтле булуы.

3. Мал-мөлкәт Аллаһныкы һәм Ул аны Үзе теләгән кешегә бирә.

4. Аллаһ Үз рәхмәте белән фәкыйрьне баета ала. Хакимлеккә кемнең лаек икәнлеген Ул яхшы белә (Фәхреддин Разый, «Тәфсир», VI, 147).

Талутның хөкемдар булачагына каршы чыккан Исраил угыллары бу юлы: «Әгәр ул чыннан да хөкемдар икән, безгә моны раслап, берәр дәлил китерсен!» – ди.

Шуннан соң:

وَقَالَ لَهُمْ نِبِيُّهُمْ إِنَّ آيَةَ مُلْكِهِ أَنْ يَأْتِيَكُمُ التَّابُوتُ فِيهِ سَكِينَةٌ مِّن رَّبِّكُمْ وَبَقِيَّةٌ مِّمَّا تَرَكَ آلُ مُوسَى وَآلُ هَارُونَ تَحْمِلُهُ الْمَلآئِكَةُ إِنَّ فِي ذَلِكَ لآيَةً لَّكُمْ إِن كُنتُم مُّؤْمِنِينَ

**«Пәйгамбәрләре аларга: "Аның хөкемдарлыгының билгесе шул булыр ки: ул фәрештәләр күтәреп йөрткән (үз вакытында сездән алынган) табут алып килер; анда Раббыгыздан бер күңел тынычлыгы (җаннарга иминлек бирә торган хозурлык), һәм Муса гаиләсе белән Һарун гаиләсеннән калган нәрсәләр булыр. Әгәр сез ышанган кешеләр булсагыз, һичшиксез, анда сезнең өчен билге бар!" – дигән иде»** («әл-Бәкара», 248).

Табут турында төрле риваятьләр бар. Аларның кайберләре буенча, табут башта Адәм галәйһис-сәләәмгә бирелә. Аннан Шит галәйһис-сәләәмгә күчә, соңыннан үз чиратында Ибраһим, Ягъкуб һәм Муса галәйһимәс-сәләмгә күчеп бара. Муса галәйһис-сәләәм Тәүрат такталарын һәм башка кайбер мөһим нәрсәләрне шул табут дип йөртелгән сандык эченә куя. Хәрби походлар вакытында табутны гаскәрләр алдыннан күтәреп баралар. Шул рәвешле гаскәрләрнең сугышчан дәрте күтәрелә, рухлары ныгый, көче арта.

Ахырда исә Аллаһ Тәгалә фәрештәләр аша табутны Талутның өенә куйдыра. Моны күргәч, Исраил угыллары, Талутның хөкемдарлыгына ризалашып, тынычланып кала.

Шулай итеп Җәнабел-Хак Исраил угылларына Талутның хөкемдарлыгына бәйле бер билгене күрсәтә. Ләкин Аллаһ Тәгалә аларның иман дәрәҗәсен ачыклап бирәчәк бер сынау да уздыруны максат итеп куя.

### Сынау

Хөкемдар вазифасына керешүгә, армияне ныгытып, Талут король Җалутка яу чаба. Бик эссе вакыт булганлыктан, гаскәрләрнең суга ихтыяҗы арта. Фәкать Ишмоил галәйһис-сәләәмгә Җәнабел-Хактан күрсәтмә килә. Илаһи

әмерне ишеткәч, Талут гаскәренә мөрәҗәгать итә: «Аллаһ сезне су белән сынаячак. Кем дә кем елгадан туйганчы эчә, шул минем гаскәрем түгел!..» Алларындагы елгадан бары бер уч кына су эчәргә рөхсәт бирелә.

Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмә әйтүенчә, бу елга Шәрига дип йөртелгән Иордан елгасы була (Ибне Кәсир, «Кыйсасүл-Әнбия», 511 б.).

Талут һәм аның гаскәрләре югарыда искә алынган елга ярына килеп җитә. Армия 80 мең кешедән тора. Шуларның 76 меңе, кушылганны тыңламыйча, туйганчы су эчә. Бары 4000 кеше генә әмергә буйсына. Тик соңыннан аларның да күбесе яу кырыннан качып китә һәм барлыгы 313 кеше генә кала. Бу сан Бәдер сугышына катнашкан мөэмин гаскәрләр саны белән туры килә.

Бәра радыйаллаһу ганһедән тапшырылган хәдистә болай диелә:

«Хәзрәти Мөхәммәднең сәхабәләре буларак, без болай дип әйтә идек: “Бәдердә булганнарның саны Талут белән бергә (Палестина) елгасын кичкән мөэмин гаскәрләре саны кадәр – 313”» (Бохари, «Мәгази», 6).

Елгадан бер учтан күбрәк су эчүчеләрнең сусыны тагын да көчәя, аларның иреннәре кибә, ахыр чиктә бөтенләй хәлсезләнеп егылалар. Әмерне үтәгәннәре исә шул бер уч су белән туена. Аларның иманнары ныгып, көч-куәтлыклары арта.

Аяти кәримәдә болай диелә:

فَلَمَّا فَصَلَ طَالُوتُ بِالْجُنُودِ قَالَ إِنَّ اللّهَ مُبْتَلِيكُم بِنَهَرٍ فَمَنْ شَرِبَ مِنْهُ فَلَيْسَ مِنِّي وَمَنْ لَّمْ يَطْعَمْهُ فَإِنَّهُ مِنِّي إِلاَّ مَنِ اغْتَرَفَ غُرْفَةً بِيَدِهِ فَشَرِبُواْ مِنْهُ إِلاَّ قَلِيلاً مِّنْهُمْ فَلَمَّا جَاوَزَهُ هُوَ وَالَّذِينَ آمَنُواْ مَعَهُ قَالُواْ لاَ طَاقَةَ لَنَا الْيَوْمَ بِجَالُوتَ وَجُنودِهِ قَالَ الَّذِينَ يَظُنُّونَ أَنَّهُم مُّلاَقُو اللّهِ كَم مِّن فِئَةٍ قَلِيلَةٍ غَلَبَتْ فِئَةً كَثِيرَةً بِإِذْنِ اللّهِ وَاللّهُ مَعَ الصَّابِرِينَ

**«Талут, гаскәрләр белән (Иерусалимнән) юлга чыккач: “Һичшиксез, Аллаһ сезне елга белән сынаячак. Кем дә кем аннан эчә, ул – миннән түгел. Кем дә кем аны (рөхсәт ителгәннән күбрәк) татымый, кулы белән бер уч чумырып кына ала, һичшиксез, ул – миннән!” – дип әйткән иде. Аларның күпчелеге, араларыннан бик азыннан тыш, аннан (туйганчы) эчкән иде. Ул (Талут) һәм аның янында булган иман китерүчеләр аны (елганы бергәләп) кичеп чыккач: “Бүген безнең Җалут һәм аның гаскәрләренә каршы тәкать юк”, – дип әйткәннәр иде. Үзләренең, чыннан да, Аллаһ белән күрешәчәкләрен шиксез белүчеләр исә: “Аллаһның насыйп итүе белән күпме аз санлы төркем бик күп зур төркемнәрне җиңде. Аллаһ сабыр итүчеләр белән”, – дигән иде»** («әл-Бәкара», 249).

Аяти кәримәдә хәрби дисциплинага игътибар юнәлтелә. Теге яки бу армиянең өстенлеге, җиңүләргә сәләтлелеге иң беренче чиратта, командирның

фәрманнарына берсүзсез буйсынудан тора. Сугышта җиңү санга түгел, хаклылыкка, дөреслеккә, иман һәм рухи ныклыкка бәйле. Җиңүче таҗын микъдардан бигрәк, сыйфатка ия гаскәрләр кия. Сәгадәт чоры сугышлары моның иң ачык мисалы булып тора. Якын тарихыбыздагы Чанаккалә сугышы[139] да әлеге хакыйкатьнең иң камил бер мисалын тәшкил итә.

**Хәзрәти Давыт һәм җиңү**

Талутның армиясендә 18 яшьлек Давыт исемле бер егет була. Бәйдави сүзләренчә, Давыт галәйһис-сәләәм Талут армиясенә атасы һәм унөч туганы белән бергә кушыла.

Давыт галәйһис-сәләәм сарык көтүе көтеп гомер итә. Бауга эләктерелгән каештан гыйбарәт корал – сапан белән таш атарга оста бик батыр егет була. Беркөнне ул атасына: «Бөтен таулар-ташлар минем белән бергә тәсбих әйтә!» – ди. Шуннан соң атасы: «И, Давыт, бу синең өчен яхшы хәбәр булсын!» – дип сөендерә.

Давыт галәйһис-сәләәмнең тавышы бик көр һәм матур булганга, аны Талут янына алып киләләр. Талут аны үзенең сөрәнчесе итеп билгели. Давыт галәйһис-сәләәм шулвакытта Талутның амаликага каршы яуга әзерләнгән армиясенә кушыла.

Аллаһ пәйгамбәренә (Ишмоил галәйһис-сәләәмгә) Давытның Җалутны үтерәчәге турында хәбәр итә, шуңа күрә Талут Давытны үзе белән яуга ала. Юлда өч таш телгә килеп, Давытка: «Безне дә ал, Җалутны безнең белән үтерәчәксең!» – дип әйтә. Давыт галәйһис-сәләәм аларны үзе белән ала, соңыннан бу өч таш, берләшеп, бер ташка әйләнә.

Яу алдыннан Талут: «Җалутны кем үтерә, шуңа кызымны бирәчәкмен!» – дип вәгъдә итә.

Ниһаять, Талутның 313 кешегә калган иманлы гаскәрләре дошман белән йөзгә-йөз килә. Аяти кәримәдә болай диелә:

وَلَمَّا بَرَزُوا لِجَالُوتَ وَجُنُودِهِ قَالُوا رَبَّنَا أَفْرِغْ عَلَيْنَا صَبْرًا وَثَبِّتْ أَقْدَامَنَا وَانْصُرْنَا عَلَى الْقَوْمِ الْكَافِرِينَ

**«Алар (Талут гаскәре) Җалут һәм гаскәрләре белән очрашкач: “И, Раббыбыз! Өстебезгә чыдамлык яудыр, аяк табаннарыбызны ныгыт һәм кяферләр кавеменә каршы безгә ярдәм ит!” – дигәннәр иде»** («әл-Бәкара», 250).

Әлеге аяти кәримәдә дошманга каршы яу белән килгән гаскәрнең өч сыйфатка ия булуы зарурилыгына ишарә ителә:

1. Авырлыкларга сабыр итү;
2. Кыюлык һәм карарлылык;

139. Чанаккалә сугышы – Беренче Бөтендөнья сугышында Дарданелла бугазындагы зур хәрби бәрелеш.

3. Илаһи ярдәмнең киләчәгенә ихлас ышанып, Җәнабел-Хакка ялвару.

Ике армия очрашкач, Җалут үзе белән көч сынашачак, ягъни гаскәрнең бер вәкиле сыйфатында аның белән бергә-бер сугышачак берәр ир-егет чыгарырга куша. Аның каршына Давыт галәйһис-сәләәм чыга. Һәркем гаҗәпкә кала, чөнки Җалут зур гәүдәле, бик көчле адәм була. Шуңа да Җалут, үз көченә ышанып, Давытны кимсетеп: «Әй, көчек, син чыктыңмы каршыма? Сөйлә, ник килдең?» – дип сүзката. Давыт: «Синең белән сугышырга килдем!» – дигәч, Җалут аны мыскыллап көлә. Давыт галәйһис-сәләәм сапанын чыгара да, югарыда искә алынган ташны куеп, Җалутка ыргыта. Таш Җалутның нәкъ маңгаена тия һәм Җалут, атыннан егылып төшеп, үлә.

Үз көче белән масаеп йөргән, зур гәүдәле хөкемдар булган Җалут, аермачык тышкы өстенлегенә карамастан, оттыра. Аллаһ Тәгалә моның белән эш-хәлләрнең тышкы шартларга гына бәйле булмыйча, асылда Аның ихтыяры белән чынга ашканын күрсәтә. Шулай ук әлеге вакыйгага аша кешеләр күзендә көчле булып күренгәннең чынлыкта зәгыйфь, ә көчсез, мескен булып күренгәннең исә Аллаһ ярдәме белән куәтле була алачагын белдерә. Аллаһны инкяр итүче залимнәр никадәр көчле күренсәләр дә, Аллаһның ихтыяры чынга ашкан чакта, нәни баладан да зәгыйфьрәк хәлгә калырлар. Әбрәһә мисалындагы кебек...

Монда Аллаһ Тәгалә чынга ашырырга ниятләгән башка хикмәтләр дә бар: Хак Тәгалә Талуттан соң хакимлекне Хәзрәти Давытның алуын һәм соңрак улы Сөләйман галәйһис-сәләәмне үз варисы итүен күз уңында тота. Хәзрәти Давытның Җалутны үтерүе халык каршында аның көчен, батырлыгын исбатлый һәм шул рәвешле Давыт галәйһис-сәләәм хөкемдарлык вазифасына хәзерләнә.

Аллаһ Тәгалә аяти кәримәдә әйтә:

فَهَزَمُوهُم بِإِذْنِ اللَّهِ وَقَتَلَ دَاوُدُ جَالُوتَ وَآتَاهُ اللَّهُ الْمُلْكَ وَالْحِكْمَةَ وَعَلَّمَهُ مِمَّا يَشَاء
وَلَوْلَا دَفْعُ اللَّهِ النَّاسَ بَعْضَهُمْ بِبَعْضٍ لَّفَسَدَتِ الْأَرْضُ وَلَكِنَّ اللَّهَ ذُو فَضْلٍ عَلَى الْعَالَمِينَ

**«Алар Аллаһның ихтыяры белән аларны тар-мар иттеләр. Давыт исә Җалутны үтерде. Аллаһ аңа (Давытка) хакимлекне дә, хикмәтне дә (пәйгамбәрлек) бирде һәм аңа Үзе теләгән нәрсәләрне өйрәтте. Әгәр дә кешеләрнең берәүләрен икенчеләреннән Аллаһның яклавы булмаса, җир бозылыр иде. Әмма Аллаһ – бөтен галәмнәргә карата фазыйләт иясе»** («әл-Бәкара», 251).

Бу аяти кәримә дөнья тормышында хакимлек иткән илаһи тәртип турында билгеле бер аңлатма бирә. Чыннан да, әгәр Аллаһ Тәгалә кешеләр арасында гаделлек белән идарә итә торган җитәкчеләр булдырмаса, кешеләрнең көчлеләре зәгыйфьләрне изеп-кимсетеп бетерер иде. Бу яктан караганда, рива-

ять кылынган бер хәдисне искә алырга мөмкин: «Солтан – Аллаһның җир йөзендәге шәүләсе ул». (Хәйсәми, «Мәҗмагуз-Зәваид», V, 196, Дәйләми, «Мүснәд», II, 343).

Хәзрәти Госман радыйаллаһу ганһе: «Һичшиксез, Аллаһ Коръән белән тыймаган нәрсәне солтан белән тыяр», – дип әйткән (Ибне Кәсир, «Кыйсасүл-Әнбия», 516 б.).

Икенче яктан караганда исә, Аллаһ Тәгалә кешеләр арасында иҗтимагый баланс урнашуны берничә сәбәпкә бәйләгән. Шул нигездә кешеләрнең бер өлеше бай, бер өлеше ярлы, кайберләре көчле, кайберләре зәгыйфь, бер өлеше сау-сәламәт, бер өлеше авыру, бер өлеше мөэмин, бер өлеше кяфер булачак, ләкин алар арасында корылырга тиешле мөнәсәбәтләр кешеләрнең җәмгыять рәвешендә яшәвен тәэмин итә алсын. Электрик көчәнешле уңай һәм тискәре полюслар арасында очкын һәм энергия барлыкка килгән кебек, уңай һәм тискәре холыклы кешеләр арасында формалаша торган көрәш-сугышларда бик күп хикмәтләр бар. Менә югарыдагы аяти кәримәләр белән илаһи тәртипнең кайбер нигез принциплары ачыклана. Әлеге аяти кәримәләрнең дәвамында болай диелә:

تِلْكَ آيَاتُ اللهِ نَتْلُوهَا عَلَيْكَ بِالْحَقِّ وَإِنَّكَ لَمِنَ الْمُرْسَلِينَ

**«Бу – Аллаһның аятьләре ки, аларны Без сиңа хаклык белән укыйбыз. Һичшиксез, син – (Аллаһ тарафыннан) җибәрелүчеләрдән (пәйгамбәрләрдән)!»** («әл-Бәкара», 252).

Талут җиңү белән кулга төшерелгән барлык ганимәтләрне утта яндырта, чөнки Муса галәйһис-сәләамнең шәригатенә күрә, хәләл булмаганлыктан, ганимәт малы яндырылырга тиеш дип санала.

Талут Иерусалимгә кайткач, Ишмоил галәйһис-сәләам аңа: «Җәнабел-Хак сиңа сөенечле хәбәр итеп җибәргән җиңүне насыйп кылды. Хәзер инде син дә биргән сүзеңне тот!» – ди. Шулай итеп, Талут кызын Давыт галәйһис-сәләам белән өйләндерә.

Талутның вафатыннан соң, Давыт галәйһис-сәләам хөкемдар вазифасына керешә. Күпмедер вакыттан соң аңа пәйгамбәрлек бирелә. Шул рәвешле ул үзенә хакимлек тә, нәбилек тә бирелгән тәүге пәйгамбәр була. Рухи фазыйләт һәм сәләтлелек ягыннан аңа башкалардан өстенлек насыйп ителә. Аяти кәримәдә әйтелгәнчә, аңа дүрт олуг китапның берсе булган Зәбур иңдерелә:

وَرَبُّكَ أَعْلَمُ بِمَنْ فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَلَقَدْ فَضَّلْنَا بَعْضَ النَّبِيِّينَ عَلَى بَعْضٍ وَآتَيْنَا دَاوُودَ زَبُورًا

**«Синең Раббың күкләрдә һәм җирдә булганнарны белә. Һичшиксез, Без пәйгамбәрләрнең кайберләрен кайберләреннән өстен кылдык. Давытка исә Зәбурны бирдек»** («әл-Исра», 55).

Давыт галәйһис-сәләәм гомере буе гаделлек белән идарә итә. Үзенең килеш-кыяфәтен үзгәртеп, ул халык арасына чыгып йөри, үзе башкарган эшләрдән һәм тормыш-көнкүрештән канәгатьме-түгелме икәнлекләрен, аның хакында ни уйлаганнарын сораштыра. Аның идарәсе турында сорауларга тискәре җавап бирүче, зарланучы һичкем табылмый (Куртуби, «Тәфсир», XIV, 266). Бөтен халык Давыт галәйһис-сәләәмгә буйсына.

Аяти кәримәдә:

اصْبِرْ عَلَى مَا يَقُولُونَ وَاذْكُرْ عَبْدَنَا دَاوُودَ ذَا الْأَيْدِ إِنَّهُ أَوَّابٌ

**«(Рәсүлем!) Алар сөйләгән нәрсәләргә сабыр ит һәм Безнең куәт иясе Давыт колыбызны искә төшер. Һичшиксез, ул (Аллаһка) күп тәүбә итүче иде»**, – дип әйтелә («Сад», 17).

Риваятькә күрә, Давыт галәйһис-сәләәм гыйбадәт мәсьәләсендә бик түземлек күрсәтә, бу гамәлне бик теләп, шатланып үти. Ул көнаралаш ураза тота. Соңыннан шушы тәртиптә тотыла торган уразаны Давыт уразасы дип йөртә башлыйлар.

Давыт галәйһис-сәләәм Аллаһ Тәгаләгә гыйбадәт кылу өчен иң фазыйләтле вакытларны эзли. Беркөнне ул Җәбраил галәйһис-сәләәмнән: «И, Җәбраил! Кайсы вакыт өстенрәк?» – дип сорый. Җәбраил галәйһис-сәләәм: «Әй, Давыт! Сәхәр вакытында гареш тетрәгән вакыттан башканы белмим», – дип җавап бирә (Әхмәд ибне Ханбәл, «Зүһд», 70 б.; Ибне Әби Шәйбә, «Мусаннәф», XIII, 240).

Давыт галәйһис-сәләәм төннең өчтән берен генә йоклап уздыра, калган сәгатьләрдә исә гел гыйбадәт кыла.

Аллаһ Тәгалә аяти кәримәләрдә болай дип хәбәр итә:

إِنَّا سَخَّرْنَا الْجِبَالَ مَعَهُ يُسَبِّحْنَ بِالْعَشِيِّ وَالْإِشْرَاقِ وَالطَّيْرَ مَحْشُورَةً كُلٌّ لَهُ أَوَّابٌ

**«Без тауларны да (аңа) буйсындырдык, алар аның белән бергә көннең ахырында һәм кояш чыккан вакытта тәсбих итәләр иде. Тупланган кошларны да (аңа буйсындырдык). Һәммәсе дә (зикеренә кушылу өчен) аңа җыелалар иде»** («Сад», 18–19).

وَسَخَّرْنَا مَعَ دَاوُودَ الْجِبَالَ يُسَبِّحْنَ وَالطَّيْرَ وَكُنَّا فَاعِلِينَ

**«...Давыт белән бергә тауларны һәм кошларны әмергә (Давытка) буйсындырдык ки, алар тәсбих әйтәләр иде. Без (боларны) кылучылар булдык»** («әл-Әнбия», 79).

Җәнабел-Хак Давыт галәйһис-сәләәмгә яңгырап торган матур тавыш насыйп итә. Ул Зәбурны укыганда, барлык кыргый хайваннар аның тирәсенә җыелып тыңлый торган була. Аллаһ Тәгалә Давыт галәйһис-сәләәмгә көбә

ясау сәнгатен дә өйрәтә, бу мәсьәләдә пәйгамбәр искиткеч кодрәт, осталык белән эшли. Аяти кәримәләрдә әйтелә:

وَلَقَدْ آتَيْنَا دَاوُودَ مِنَّا فَضْلًا يَا جِبَالُ أَوِّبِي مَعَهُ وَالطَّيْرَ وَأَلَنَّا لَهُ الْحَدِيدَأَنِ اعْمَلْ سَابِغَاتٍ وَقَدِّرْ فِي السَّرْدِ وَاعْمَلُوا صَالِحًا إِنِّي بِمَا تَعْمَلُونَ بَصِيرٌ

**«Без Давытка Үзебездән фазыйләт бирдек. “И, таулар һәм кошлар! Аның белән бергә тәсбих әйтегез!” (дидек). Тимерне аның өчен йомшарттык. (Аңа): “Салынып торган көбә киемнәр яса һәм үлчәүле (матур һәм җитәрлек) ит. Сез (әһелең белән бергә) изге гамәл кылыгыз. Һичшиксез, Мин – сезнең ни кылганнарыгызны күрүчемен” (дип вәхи кылдык)»** («Сәбә», 10–11).

وَعَلَّمْنَاهُ صَنْعَةَ لَبُوسٍ لَكُمْ لِتُحْصِنَكُمْ مِنْ بَأْسِكُمْ فَهَلْ أَنْتُمْ شَاكِرُونَ

**«Сугышыгыздан сезне сакласын, дип, кием сәнгатен Без аңа сезнең өчен өйрәттек. Ләкин сез шөкер итәсезме соң?»** («әл-Әнбия», 80).

Көбә ясап, Давыт галәйһис-сәләәм гаскәрләрен дә дошманнардан саклый, үзенә ризыкны да кул көче белән эшләп тәэмин итә. Мөлкәт һәм сәяси абруй иясе, икътисади мөмкинлекләре киң пәйгамбәр булуына карамастан, ул кул хезмәте белән тормыш алып баруга өстенлек бирә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез хәдисе дә моны раслый: *«Һичкем үзе эшләп тапканнан хәерлерәк ризык ашамаган. Аллаһның пәйгамбәре Давыт галәйһис-сәләәм дә үз кул хезмәте белән туенган»* (Бохари, «Бүйуэ», 15; «Әнбия», 37).

Хәзрәти Давыт галәйһис-сәләәм, илаһи ярдәмгә лаек булып, аңа берничә сакчы бирелә. Зур-зур армияләр белән җитәкчелек итү, абруй казану кебек мәсьәләләрдә аңа мул өлеш чыгарыла. Давыт галәйһис-сәләәм пәйгамбәрлек, алдан күрүчәнлек, китап, шәригать, гыйлем, гамәл, матур сөйләшү һәм хикмәт иясе була. Аллаһ Тәгалә болай дип белдерә:

وَشَدَدْنَا مُلْكَهُ وَآتَيْنَاهُ الْحِكْمَةَ وَفَصْلَ الْخِطَابِ

**«Без аның хакимлеген куәтләдек, аңа хикмәт белән аера торган сөйләү (фаслы-хитаб – хакны батыйльдән аеру сәләте) бирдек»** («Сад», 20).

«Фаслы-хитаб» сүзтезмәсе, мөфәссир Сүдди фикеренчә, вакыйганы тулысынча аңлау һәм бирелгән хөкемне күздә тотып бәян кылу дигәнне белдерә. Мөҗәһид әйтүенчә, бу сүзләр эш-гамәлдә реалист һәм практик дигәнне аңлата.

Җәнабел-Хак Давыт галәйһис-сәләәмгә болай дип мөрәҗәгать итә:

يَا دَاوُودُ إِنَّا جَعَلْنَاكَ خَلِيفَةً فِي الْأَرْضِ فَاحْكُمْ بَيْنَ النَّاسِ بِالْحَقِّ وَلَا تَتَّبِعِ الْهَوَىٰ فَيُضِلَّكَ عَنْ سَبِيلِ اللَّهِ إِنَّ الَّذِينَ يَضِلُّونَ عَنْ سَبِيلِ اللَّهِ لَهُمْ عَذَابٌ شَدِيدٌ بِمَا نَسُوا يَوْمَ الْحِسَابِ

**«И, Давыт! Һичшиксез, Без сине җирдә бер хәлифә итеп билгеләдек. Кешеләр арасында хак белән хөкем бир, начар теләккә иярмә, юкса ул сине Аллаһның юлыннан яздырыр. Һичшиксез, Аллаһның юлыннан язганнарга, хисап көнен онытулары сәбәпле, каты газап бар»** («Сад», 26).

Пәйгамбәр дә, шул ук вакытта хөкемдар да булган Давыт галәйһис-сәләәм көндәлек вакытын дүрткә бүлә. Көннең бер өлешендә гыйбадәт белән мәшгуль була. Икенче вакытта исә хокукый бәхәсләрне хәл итә. Өченче өлештә халыкка вәгазь-нәсыйхәт укый. Дүртенче өлештә шәхси эшләрен башкара.

### Давыт галәйһис-сәләәмнең сыналуы

Давыт галәйһис-сәләәм төрле сынауларга дучар ителә, нәтиҗәдә аңа бәндәчел зәгыйфьлекләре һәм ихтимал хаталары белдерелә. Ул шундук тәүбәгә каплана һәм шул рәвешле Җәнабел-Хак, аны ярлыкап, мәңгелеккә бару юлында янаган куркынычлар турында өйрәтә.

Беркөнне, Давыт галәйһис-сәләәм гыйбадәт кылу белән мәшгуль чакта, ике кеше килә. Аулакта гыйбадәт һәм зикер кылган вакытта, аның янына гыйбадәтханәгә беркем дә керми торган була. Көтелмәгән бу хәл каршында Хәзрәти Давыт галәйһис-сәләәм кәефсезләнә, чөнки ишеге ябык гыйбадәтханәгә моңарчы һичкем шушылай килеп керә алмаган. Үзенең гыйбадәт вакыты икәнен никадәр генә аңлатырга тырышса да, теге ике бәндә аны тыңламый. «Гыйбадәтнең көне юк аның!» – дип, үзләренең йомышларын әйтеп бирәләр: «Курыкма! Без – бер-беребезнең хак-хокукын бозган ике дәгъвачы. Синең каршыга хөкем ишетү өчен килдек. Арабызда гаделлек белән хөкем чыгар!» Давыт галәйһис-сәләәм: «Алайса, сөйләгез!» – ди. Ике дәгъвачының берсе хәлне аңлатып бирә: «Туганымның – 99 сарыгы, минем исә бер сарыгым бар. Шуңа карамастан, ул миндәге шул бердәнбер сарыкны да үзенә тартып алырга теләде һәм мине бәхәстә җиңде».

Давыт галәйһис-сәләәм, бу хәлнең хаксызлык икәнен уйлап, бик тәэсирләнә һәм, икенче яктан һични сорап тормыйча: «Шул бердәнбер сарыгыңны да алырга теләсә, туганыңның бу гамәле сиңа карата золым санала. Аллаһ Тәгаләгә иман китермәгән затлар шулай явызлык кыла. Яхшы кешеләр бик аз ул», – дип белдерә. Теге ике бәндә көлеп китеп бара.

Давыт галәйһис-сәләәм хөкем итүдә ашыгып эш йөртә һәм каршы якны бөтенләй тыңлап тормыйча карар чыгара. Югыйсә каршы як сүзләренә колак салган очракта, мәсьәләнең бөтен рәвеше яки аның бер өлеше үзгәрергә мөмкин; хаклы дип саналган зат асылда хаксыз, ә хаксыз күренгәне хаклы булып чыга ала. Шуңа күрә Давыт галәйһис-сәләәм, дәгъвачылар китүгә үк, үзенең ялгышканын аңлый һәм, моның илаһи сынау икәнлеген төшенеп, шундук сәҗдәгә каплана, тәүбә-истигъфар кыла. Аллаһ Тәгалә исә аны гафу итә.

Болар – хәтта пәйгамбәрләргә дә Аллаһ Тәгалә каршындагы гаҗизлекләрен төшендерү һәм аларга иярүчеләр үрнәк алачак эш-гамәлләрнең нигезен тәэмин итү хикмәтенә бәйле рәвештә чынга ашкан вакыйгалар. Бу хәлләр аларның пәйгамбәрлегенә һәм әлеге вазифага хас гөнаһсызлык сыйфатына һич тә китеклек салмый. Мөфәссир күзлегеннән, мондый сынаулар «хасәнәтүл-әбрар, сәййиатүл-мукаррабин»[140] хөкемендә карала, ягъни пәйгамбәрләрнең гамәлләре хата булып күренгән вакыйгалар без шундый ук хата кылган очракта нишләргә тиешлегебезне күрсәтү өчен килеп чыккан һәм сурәтләп бирелгән.

Бу вакыйга Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә бәян ителә:

وَهَلْ أَتَاكَ نَبَأُ الْخَصْمِ إِذْ تَسَوَّرُوا الْمِحْرَابَ إِذْ دَخَلُوا عَلَىٰ دَاوُودَ فَفَزِعَ مِنْهُمْ قَالُوا لَا تَخَفْ
خَصْمَانِ بَغَىٰ بَعْضُنَا عَلَىٰ بَعْضٍ فَاحْكُمْ بَيْنَنَا بِالْحَقِّ وَلَا تُشْطِطْ وَاهْدِنَا إِلَىٰ سَوَاءِ الصِّرَاطِ

**«(И, Мөхәммәд!) Сүз көрәштерә башлаганнар турында хәбәр сиңа ирештеме? Менә алар михраб дивары аша үрмәләп үттеләр. Алар Давыт янына керделәр, ул (Давыт) алардан куркып китте. Әйттеләр: “Курыкма, ике дошман, беребез икенчесенә карата хаксызлык кылды. Син арабызда хак белән хөкем бир дә, чиктән чыкма һәм безне юлның турысына ирештер”»** («Сад», 21–22).

إِنَّ هَٰذَا أَخِي لَهُ تِسْعٌ وَتِسْعُونَ نَعْجَةً وَلِيَ نَعْجَةٌ وَاحِدَةٌ فَقَالَ أَكْفِلْنِيهَا وَعَزَّنِي فِي الْخِطَابِ

**«(Аларның берсе болай диде:) “Менә бу минем кардәшем, аның туксан тугыз сарыгы бар, минем исә бер сарыгым бар. Ул аны миңа бир, диде һәм сүзләре белән мине җиңде”»** («Сад», 23).

قَالَ لَقَدْ ظَلَمَكَ بِسُؤَالِ نَعْجَتِكَ إِلَىٰ نِعَاجِهِ وَإِنَّ كَثِيرًا مِنَ الْخُلَطَاءِ
لَيَبْغِي بَعْضُهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ إِلَّا الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ وَقَلِيلٌ
مَا هُمْ وَظَنَّ دَاوُودُ أَنَّمَا فَتَنَّاهُ فَاسْتَغْفَرَ رَبَّهُ وَخَرَّ رَاكِعًا وَأَنَابَ

**«(Давыт:) “Синең сарыгыңны үзенең сарыкларына кушарга теләве белән ул сиңа карата гаделсез эш иткән. Һичшиксез, иман китергән һәм изге гамәлләр кылучылар булмаса, кушып берләштерүчеләрдән бик күбесенең берләре икенчеләренә карата гаделсез эш итә. Әмма алар бик аз”. Давыт Безнең аны сынавыбызны шиксез белде һәм шундук Раббысыннан мәгъфирәт сорады, рөкүгъ белән җиргә капланды һәм (тәүбә белән Аллаһка) юнәлде»** («Сад», 24).

140. Әбрар (хәерле, күркәм эшләр кылучылар һәм тәкъвалык ияләре) затлар өчен савап (хасән) саналган кайбер эш-гамәлләр алардан югарырак дәрәҗәдәге мукаррәбләр (Аллаһка бик якын коллар) өчен гөнаһ (сәййия) дип кабул ителә.

فَغَفَرْنَا لَهُ ذَلِكَ وَإِنَّ لَهُ عِنْدَنَا لَزُلْفَى وَحُسْنَ مَآبٍ

**«Без (бу гамәле сәбәпле) аңа моны кичердек. Һичшиксез, ул Безгә якын һәм аның өчен күркәм кайту урыны бар»** («Сад», 25).

Давыт галәйһис-сәләәм кыямәт көнне Аллаһка якын кол булачак. Хәдис-шәрифтә әйтелә:

*«Гаделлек белән хөкем кылучылар кыямәт көнендә Рахманның уң ягында нурдан гыйбарәт мөнбәрләр өстендә булачак... Алар хөкемнәрендә гаиләләре һәм үзләре җаваплы затларга карата гадел мөнәсәбәттә булдылар»* (Ибне Ханбәл, II, 160).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Кыямәт көнендә кешеләрнең Аллаһ Тәгаләгә иң сөеклесе һәм Аңа иң якын урында булганы – гадел идарәче. Кыямәт көнендә кешеләрнең Аллаһ Тәгаләгә иң сөексезе һәм Аңа иң ерак арада торганы – залим идарәче»*, – дип тә әйткән (Тирмизи, «Ахкам», 4; Нәсаи, «Зәкят», 77).

Хәзрәти Давыт галәйһис-сәләәм турында югарыда телгә алынган аяти кәримәләрнең эчтәлегенә тулысынча каршы килеп, кеше кулы белән үзгәртелгән Тәүрат һәм Инҗилләрдә чынбарлыкка ят бер кочак вакыйгалар бәян ителә һәм пычрак яла-ялганнар урын ала. Бу мәсьәләдә Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе: «Кем дә кем Давыт вакыйгасын әкиятчеләр риваять кылган кебек (ялгыш һәм әшәке формада) сөйләсә, аңа йөз алтмыш таяк сугармын!» – дигән.

Һичшиксез, Хәзрәти Давытка Аллаһның олуг катында якынлык, күркәм урын һәм җәннәттә матур бер җир әзерләнгән.

**Әсхабе Сәбт вакыйгасы**

Әсхабе Сәбт (Шимбә ияләре) Мисыр белән Мәдинәи Мөнәввәрә арасында, Кызыл диңгез буендагы Мәдйән шәһәрендә яши. Саннары якынча җитмеш мең чамасы тәшкил итә. Алар шимбә көнне бары гыйбадәт кенә кылалар, чөнки шимбә көнне гыйбадәттән кала башка эшләр хәрәм санала. Ул көнне ауга чыкмау турында Давыт галәйһис-сәләәмгә сүз бирәләр. Ләкин соңрак шайтан аларның күңеленә вәсвәсә сала: «Сез балык аулаудан түгел, ризыктан чикләндегез!» – дип котырта.

Илаһи хикмәт буларак, шимбә көнне балыклар күбәя, бүтән көннәрдә азая торган була. Шунлыктан шайтанның котыртуы кайберләренең күңеленә хуш килә. Бу мәсьәләдә Мәдйән халкы өч төркемгә аерыла:

1 нче төркем, Аллаһның әмеренә каршы килеп, балык тота башлый. Аны үзләре дә ашый, башкаларга да сата. Болар шимбә көнне ятьмә сала, якшәмбе көнне аны тартып чыгаралар.

2 нче төркемдәгеләр балык тоту гөнаһына бармый, ләкин илаһи әмергә буйсынмаганнарга каршы чыкмыйлар, ягъни илаһи әмернең аяк астына салып тапталуын күреп тә, дәшми калалар, һич үгет-нәсыйхәт кылмыйлар.

3 нче төркемдәгеләр исә Аллаһ кушканга да буйсына, шимбә көнгә бәйле тыюны бозганнарга кисәтү ясап, аларга үгет-нәсыйхәт тә укый. Дәшми калучыларга да дөрес эшләмәгәнлекләре турында аңлаталар. Шул рәвешле алар «әмри бил-мәгъруф вә нәһйи ганил-мүнкәр» вазифасын үтиләр.

Дәшми калучылар төркеме үзләренә кисәтү ясаучыларга: «Һәлак ителәчәк кавемне вәгазьләп, ник тиккә көчегезне әрәм итәсез? Салган тырышлыгыгыз кызганыч!» – дип әйтә. «Әмри бил-мәгъруф», ягъни яхшылыкка өндәү белән шөгыльләнүчеләр: «Без Җәнабел-Хак каршында җавап тотарга туры килмәсен, кичерелгәннәр булыр өчен шулай эшлибез!» – дип җавап бирәләр.

Соңрак болар, башкаларга киләчәк бәла-авырлыклар үзләренә дә килә күрмәсен, дип, ике арада бер дивар кора. Диварның теге ягындагы тавышлар тынгач, карасалар, бер төн эчендә барысы да берьюлы маймылга әверелгән!.. Илаһи хөкемгә колак салмаганнары өчен, әнә шундый җәзага тартылган бу бәдбәхетләр, мондый газаптан Аллаһның әмеренә буйсынганга күрә котылган туганнары янында күпмедер вакыт кайгырып йөриләр. Өч көннән соң исә маймылга әверелгән ул кяферләр барысы да үлә.

Имам Бәгавинең «Мәгалимүт-Тәнзил» хезмәтендә: «Ауга чыкмаганнар, ләкин ауга чыгучыларны һич кисәтмичә һәм үгетләмичә, дәшми калган бәндәләр дә, шул ауга чыгучылар белән маймыл кыяфәтенә кертелә», – дип әйтелә.

Коръәни-Кәримдә бу вакыйга болай бәян ителә:

وَاسْأَلْهُمْ عَنِ الْقَرْيَةِ الَّتِي كَانَتْ حَاضِرَةَ الْبَحْرِ إِذْ يَعْدُونَ فِي السَّبْتِ إِذْ تَأْتِيهِمْ
حِيتَانُهُمْ يَوْمَ سَبْتِهِمْ شُرَّعًا وَيَوْمَ لَا يَسْبِتُونَ لَا تَأْتِيهِمْ كَذَلِكَ نَبْلُوهُمْ بِمَا كَانُوا يَفْسُقُونَ

**«Алардан диңгезгә якын булган урын (шәһәр халкы хәле) турында сора. Алар шимбәдә (хөрмәтсезлек күрсәтеп) чиктән аштылар, чөнки шимбә көннәрендә балыклар күренеп, аларга киләләр, шимбә булмаган көннәрдә исә аларга килмиләр иде. Бозыклык кылганнары өчен, Без аларны әнә шулай сынадык»** («әл-Әгъраф», 163).

وَإِذْ قَالَتْ أُمَّةٌ مِنْهُمْ لِمَ تَعِظُونَ قَوْمًا اللَّهُ مُهْلِكُهُمْ أَوْ مُعَذِّبُهُمْ
عَذَابًا شَدِيدًا قَالُوا مَعْذِرَةً إِلَىٰ رَبِّكُمْ وَلَعَلَّهُمْ يَتَّقُونَ

**«Араларыннан бер җәмәгать: “Аллаһ һәлак итәчәк яки бик каты бер газап белән газаплаячак җәмәгатьне ни дип үгетлисез?” – диделәр. Алар**

**(нәсыйхәт итүчеләр): “Раббыбыз алдында аклану өчен. Һәм, бәлки, алар куркырлар (дигән өмет белән нәсыйхәт кылабыз)”, – диделәр»** («әл-Әгъраф», 164).

فَلَمَّا نَسُوا مَا ذُكِّرُوا بِهِ أَنْجَيْنَا الَّذِينَ يَنْهَوْنَ عَنِ السُّوءِ
وَأَخَذْنَا الَّذِينَ ظَلَمُوا بِعَذَابٍ بَئِيسٍ بِمَا كَانُوا يَفْسُقُونَ

**«Алар үгетләнгән нәрсәне оныткач, Без начарлыктан тыючыларны коткардык. Залим булган кешеләрне исә кылган бозыклыклары аркасында каты газап белән тоттык. Алар үзләренә тыелган нәрсәдән тәкәбберләнгәч (баш тартмагач), Без аларга: “Хур ителгән маймыллар булыгыз!” – дидек»** («әл-Әгъраф», 165–166).

Җәнабел-Хак соңыннан киләчәк буыннарны, әлеге вакыйга турында искә алып, түбәндәгечә кисәтеп куя:

وَلَقَدْ عَلِمْتُمُ الَّذِينَ اعْتَدَوْا مِنْكُمْ فِي السَّبْتِ فَقُلْنَا لَهُمْ كُونُوا قِرَدَةً خَاسِئِينَ

**«(Әй, Исраил угыллары!) Һичшиксез, арагыздагы шимбәдә чикләрдән чыкканнарны сез яхшы беләидегез. Без аларга: “Җирәнгеч маймыллар булыгыз!” – дип әйткән идек»** («әл-Бәкара», 65).

فَجَعَلْنَاهَا نَكَالًا لِمَا بَيْنَ يَدَيْهَا وَمَا خَلْفَهَا وَمَوْعِظَةً لِلْمُتَّقِينَ

**«Шул рәвешчә Без моны алардан алда булган буынына да, алардан соң булганнарга да гыйбрәт, тәкъвалык ияләренә нәсыйхәт иттек»** («әл-Бәкара», 66).

Әйлә халкы шимбә көнне Аллаһ кушканнардан йөз чөереп, үз җаннарына золым иткән вакытта, Давыт галәйһис-сәләәм аларга ләгънәт укый һәм бу халык маймылга әверелә (Әлмалылы Х. Языр, Хак Дини Куран Дили, III, 1786).

Әлеге вакыйганың Давыт галәйһис-сәләәм вакытында булганына менә бу аяти кәримә дә ишарәли:

لُعِنَ الَّذِينَ كَفَرُوا مِنْ بَنِي إِسْرَائِيلَ عَلَىٰ لِسَانِ دَاوُودَ
وَعِيسَى ابْنِ مَرْيَمَ ذَٰلِكَ بِمَا عَصَوْا وَكَانُوا يَعْتَدُونَ

**«Исраил улларыннан кяфер булган кешеләр Давыт һәм Мәрьям улы Гайсәнең теле белән ләгънәтләнделәр...»** («әл-Маидә», 78).

Мөселманнар бөтен пәйгамбәрләргә ышанганга, алар арасында ниндидер өстенлек, аермалык күрсәтмәгәнгә һәм Хәзрәти Гайсәне дә пәйгамбәр итеп кабул иткәнгә күрә, яһүдиләр: «Без сезнең динегездән дә начаррак динне белмибез!» – дигәннәр.

Шуннан соң түбәндәге аяти кәримә иңдерелә:

قُلْ هَلْ أُنَبِّئُكُمْ بِشَرٍّ مِنْ ذَٰلِكَ مَثُوبَةً عِنْدَ اللَّهِ مَنْ لَعَنَهُ اللَّهُ وَغَضِبَ عَلَيْهِ وَجَعَلَ مِنْهُمُ الْقِرَدَةَ وَالْخَنَازِيرَ وَعَبَدَ الطَّاغُوتَ أُولَٰئِكَ شَرٌّ مَكَانًا وَأَضَلُّ عَنْ سَوَاءِ السَّبِيلِ

**«Әйт: “Сезгә Аллаһ катында җәзасы моннан да начаррак булган нәрсә хакында хәбәр итимме? Аллаһ үзләрен ләгънәтләгән һәм аларга ачу тоткан, араларыннан маймыллар һәм дуңгызларга әйләндерелгәннәр белән тагутка табынучылар – болар урыннары тагын да начаррак булган, туры юлдан ныграк тайпылучылар”»** («әл-Маидә», 60) (Вахиди, «Әсхабүн-Нүзул», 203 б.).

Аяти кәримәдә әйтелгәнчә, Аллаһ Тәгалә Бәни Исраил кавеменең әшәкелектә үҗәтлек күрсәткән ул бәдбәхетләрен әүвәл маймыл рәвешенә кертә, аннары исә һәлак итә. Кешеләрнең асылы маймылдан гыйбарәт кебек мәгънәсез фикерләрнең бу вакыйга белән бер бәйләнеше дә юк.

**Хәзрәти Давыттан калган истәлек: «Давыт уразасы»**

Көнаралаш ураза тоту буларак билгеле «сәуме Давыт» (Давыт уразасы) – Хәзрәти Давыттан Мөхәммәд өммәтенә истәлек булып калган бер гыйбадәт төре ул. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм «Давыт уразасы»н иң фазыйләтле ураза дип атаган.

Гамр ибне әл-Гас радыйаллаһу ганһенең улы Әбү Мөхәммәд Габдуллаһ радыйаллаһу ганһенең мондый сүзләре риваять кылына: «Валлаһи, гомерем буе көндез ураза тотачакмын, төнлә намаз укыячакмын», – дип ант иткәнемне Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә җиткергәннәр.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм миннән: *«Бу сүзләрне син әйттеңме?»* – дип сорады. Мин: «Ата-анам Сиңа фида булсын, йә Рәсүлүллаһ! Әйе, мин әйттем», – дидем.

Пәйгамбәр: *«Синең моңа көчең җитмәс! Кайчак ураза тот, кайчак аша; кайчак йокла, кайчак (тәһәҗҗүд) өчен йокыдан тор! Һәр ай өч көн ураза тот! Бер яхшылыкның әҗере ун тапкыр. Бу ел буе ураза тоткан кебек була»*, – дип әйтте.

«Моннан да күбрәкне башкарырга хәлемнән килә!» – дип белдердем. *«Алайса, бер көн ураза тот; ике көн ифтар кыл!»* – дип боерды.

«Моннан да күбрәкне булдыра алам!» – дидем. *«Алайса, бер көн ураза тот; бер көнне тотма! Бу – Давыт галәйһис-сәләәм уразасы, уразаларның иң өстене, иң чамалысы!»* – диде Рәсүлүллаһ.

Мин: «Моннан да күбрәгенә көчем җитә ала!» – дигәч, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм*: «Моннан артыгы булмас!..»* – дип боерды (Бохари, «Савм», 55–57, «Тәһәҗҗуд», 7; Мөслим, «Сыям», 181–193).

**Давыт галәйһис-сәләәмнең фазыйләтләре**

*Давыт галәйһис-сәләәм бөтен эшләрендә дә Аллаһка юнәлә.

*Аллаһ Тәгалә аны «колыбыз Давыт» дип искә ала.

* Давыт галәйһис-сәләәмгә дүрт бөек илаһи китапның берсе булган Зәбур иңдерелә.

*Таулар һәм кошлар аның белән бергә зикер әйтә торган була.

*Кошлар телен белә.

*Искиткеч матур тавышка ия була. Зәбурны укыган чакта, таулар һәм кошлар аны тыңлыйлар.

*Тимерне кулында балавыз кебек йомшарта. Шул рәвешле үз кул көче белән тормышын алып бара. Пәйгамбәр Әфәндебез дә аның бу халәтен мактап телгә ала.[141]

*Давыт галәйһис-сәләәмгә хакны батыйльдән аеру сәләте һәм хикмәт бирелә.

*Аның дәүләте ул заманның иң шәп һәм куәтле дәүләте була.

*Давыт галәйһис-сәләәм Раббысына бик күп шөкер итә. Бервакыт ул: «Йә, Раббы! Сиңа ничек шөкер итим соң, чөнки Сиңа шөкер итүгә бары Синең нигъмәтең-рәхмәтең белән генә ирешә алам», – дип әйтә. Аңа мондый вәхи килә: «Сиңа бирелгән нигъмәтләремнең барысының да Миннән икәнен беләсеңме?» Хәзрәти Давыт: «Әйе», – дип раслый. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә: «Менә шулай уйлавың Минем синнән риза булуыма җитәрлек», – дип белдерә (Ибне Кәсир, «Кыйсасүл-Әнбия», 524 б.).

*Кыскасы, Давыт галәйһис-сәләәм Аллаһ тарафыннан өстенлек бирелгән бер пәйгамбәр була. Аяти кәримәдә бу хакта:

وَلَقَدْ آتَيْنَا دَاوُودَ مِنَّا فَضْلًا

**«Без Давытка Үзебездән фазыйләт бирдек!..»** – диелә («Сәбә», 10).

**Давыт галәйһис-сәләәмнең үлеме**

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди:

*«Давыт галәйһис-сәләәм дин өчен бик нык тырышлык куя һәм намусының пакьлеген бик кайгырта. Өйдән чыккан чакта, ишекне яхшылап яба торган була ки, ул кайтканчы, анда берәү дә керә алмый.*

141. Карагыз: Бохари, «Бүюг», 15; «Әнбия», 37.

*Беркөнне ул өйдән чыкты, ишекне япты… Кире кайткач, Давыт галәйһис-сәләәм өйнең түрендә басып торган бер кешене күрде. Аннан: «Син кем?» – дип сорады. Тегесе: «Мин шул зат ки, патшалардан курыкмам һәм пәрдәләр (киртәләр) миңа комачаулый алмас», – диде. Шуннан соң Давыт галәйһис-сәләәм: «Валлаһи, ул очракта син – үлем фәрештәсе. Аллаһның әмере белән хуш килдең», – дип әйтте. Берникадәр вакыттан соң аның җаны алынды…»* (Әхмәд ибне Ханбәл, «Мүснәд», II, 419).

Хәзрәти Давытның кырык еллык хакимлек чоры – Исраил угылларының иң якты вакыты. Давыт галәйһис-сәләәм Иерусалимне яулап алып, аны дәүләтенең башкаласына әйләндерә. Ул бер үк вакытта хөкемдар да, пәйгамбәр дә була. Бу сыйфат аңа Хак Тәгалә тарафыннан насыйп кылына. Давыт галәйһис-сәләәмнән соң тәхет улы Хәзрәти Сөләйманга күчә һәм аңа да пәйгамбәрлек бирелә.

**Зәбур һәм аның эчтәлеге**

«Зәбур» атамасы белән бергә Коръәни-Кәримдә бу сүзнең күплек саны булган «зүбур» варианты да очрый. «Зәбур» – китап, «зүбур» китаплар дигәнне белдерә. «Зәбур» сүзе Коръәни-Кәримдә өч урында очрый һәм алар барысы да Хәзрәти Давыт белән бәйле. Аяти кәримәдә:

وَآتَيْنَا دَاوُودَ زَبُورًا

*«…Давытка исә Зәбурны бирдек»*, – дип әйтелә («ән-Ниса», 163).

«Зүбур» сүзе исә Хәзрәти Давытка мөнәсәбәтле рәвештә генә түгел, гомумән бөтен пәйгамбәрләргә иңдерелгән китаплар белән бәйле буларак телгә алына.

Коръәни-Кәримдә болай диелә:

وَإِنَّهُ لَفِي زُبُرِ الْأَوَّلِينَ

**«Һичшиксез, ул әүвәлгеләрнең китапларында иде!»** («әш-Шугара», 196).

Бу аяти кәримә бер үк вакытта Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең туачагы турында әүвәлге илаһи китапларда да сөенечле хәбәр ирештерелгәнлегенә ишарә ителә.

Хәзрәти Давытка бирелгән Зәбур турында Коръәни-Кәримдә мондый мәгълүмат бар:

وَلَقَدْ كَتَبْنَا فِي الزَّبُورِ مِنْ بَعْدِ الذِّكْرِ أَنَّ الْأَرْضَ يَرِثُهَا عِبَادِيَ الصَّالِحُونَ

**«Зикердән (Тәүраттан) соң Зәбурда да яздык инде, ул җиргә Минем изге колларым мирасчы булачак»** («әл-Әнбия», 105).

Коръәни-Кәримдә Зәбур белән бәйле шуннан артык мәгълүмат очрамый. Ислами чыганаклар Хәзрәти Давытка Зәбур иңдерелүне аның өстен сыйфатларының берсе буларак искә ала.

Ислам галимнәре Зәбурда ниндидер хөкемгә кагылышлы мәсьәләләрнең урын алмавын, аның бары тик Җәнабел-Хакка ялварудан, Аны мактау-данлау мөнәҗәтләреннән гыйбарәт икәнлеген белдерә.

Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәмнән соң килгән Хәзрәти Давыт галәйһис-сәләәм төрле хөкемнәр мәсьәләсендә Тәүрат белән гамәл кыла. Зәбур исә кешеләрдә Аллаһка карата сөю-мәхәббәтне, Җәнабел-Хакка ялвару-үтенүне камилрәк рәвештә башкаруны күздә тоткан илаһи нәзымнар тупланмасыннан гыйбарәт тулысынча шигъри китап була. Әлеге Изге китапта «Мәзмурлар» дип аталган бер бүлем бар, бу сүз көйләп укыла торган шигъри кисәкләр, әсәрләр дигәнне белдерә. Аларның саны 150гә җитә. Боларның 70ләбе Хәзрәти Давытка нисбәтләп карала, калганнары исә башкаларныкы дип санала. Шул сәбәпле бүгенге Зәбур – Коръәни-Кәримдә Хәзрәти Давытка бирелгәнлеге белдерелгән Зәбур түгел. Чөнки Изге китапның барлык бүлекләре дә иң башта иңдерелгән шәкелдә сакланып, теркәп куелмаган, хәзерге заманга кадәр аңа күп тапкыр кеше кулы кергән. Әлеге тарихи чынбарлык Зәбурның асыл, оригинал формада сакланып калу ихтималын юкка чыгара.

Бүгенге Зәбур Хәзрәти Давытның вафатыннан биш йөз ел соңрак языла башлый. Шулай ук Зәбурга Давыт галәйһис-сәләәмнең тормышы, дәгъват эшчәнлеге турында мәгълүматлар белән беррәттән чыганагы ачыкланмаган, 100гә якын билгесез шагыйрьнең шигырьләре дә өстәлгәнлеге риваять кылына.

Хәзерге замандагы Зәбурның кем тарафыннан язылганлыгы, вәхи юлы беләнме әллә илһам нәтиҗәсендәме кәгазьгә төшерелгәнлеге тулысынча ачыкланмаган. Шәрык белгече Һорн: «”Зәбур”ның Давыт пәйгамбәр тарафыннан язылганлыгын алга сөрүчеләрнең дәлилләре бик зәгыйфь, мәгънәсез; бу фикернең ялгышлыгы ап-ачык», – дип әйтә.

Зәбурдагы тәңре төшенчәсе дә Тәүраттагы кебек антропоморфик характерда, ягъни Җәнабел-Хакка билгеле бер сурәт, килеш-килбәт тагыла. Изге китапның башка бүлекләрендәге шикелле, Аллаһка угыл тагу рәвешендә тәүхид дингә каршы килә торган үзенчәлек, мәгънә салына. Бүгенге Зәбурда Давыт галәйһис-сәләәмнең бер мөнәҗәттә мондый сүзләре риваять кылына: «Раббы миңа: “Син минем улым! Мин сине бүген уллыкка алдым!” – дип әйтте» («Мәзмурлар», 2/7).

Йомгаклап әйткәндә, бүгенге Зәбур – гап-гади бер шигырь китабы гына ул. Анда Давыт галәйһис-сәләәмгә һәм башкаларга нисбәтләп каралган бер кочак мөнәҗәтләрдән кала һичнәрсә юк. Күпмесенең чын Зәбурныкы икәне дә билгесез.

# ИҢ МАТУР СҮЗНЕ МАТУР ИТЕП УКУ

Изге Китапның адресаты – кешеләр һәм җеннәргә тәэсире камил булсын өчен, Аллаһ кәламенең кыйраәте (укылышы) дөрес, хатасыз башкарылу да, шул ук вакытта аны укучының матур тавышка ия булуы да мөһим роль уйный. Нигездә, хәтта бәндә чыганаклы булганнары өчен дә яңгыраш аерымлыгы аркасында сүзләр төрле мәгънәләрдә кулланыла алган кебек, кайчак аларның тәсире көчәер, ә кайчак азаер. Бер теләнченең ялвару рәвеше, өслүбе моның өчен кулланган сүзләрдә генә түгел, шул ук вакытта аның интонациясендә дә чагылыш таба. Ут явачак, үлем чәчәчәк бер яу алдыннан командирның гаскәрләрен сугышка өндәү өчен яңгыраткан сүзләрдәге интонациясе, ягъни кәлимәләрнең аһәңе, яңгырашы, музыкасы гаскәргә куәт бирүен, билгеле бер тәэсир ясавын һичкем инкяр итә алмас. Тарихыбызда һәм мәдәниятебездә мөһим урын биләгән «мәхтәр» (хәрби оркестр) дә тәэсир көченең зурлыгы аркасында барлыкка килә һәм үсеш ала.

Гади кеше сүзләре өчен дә хас бу сыйфатның илаһи кәлам булган Коръәни-Кәрим өчен тагын да зуррак әһәмияткә ия икәнлеге ап-ачык. Бәлки, Коръәни-Кәримне укуның сөннәт, тыңлауның фарыз булуы да менә шушы хикмәткә нигезләнәдер. Мөгаен, әнә шул хакыйкать сәбәпле ислами фәннәр арасында Коръәни-Кәрим уку мөстәкыйль бер фән тәшкил итә. «Кыйраәт фәне» дип аталган бу предметның да, нәкъ мәзһәп имамнары кебек, үз имамнары барлыкка килгән.

Үзләренә китап бирелгән пәйгамбәрләрдән Давыт галәйһис-сәләәм дә, башка сыйфатларыннан бигрәк, кешелек тарихында «Дауди» буларак билгеле матур тавышы белән дә искә алына.

Коръәни-Кәрим сүзләре белән дә раслangанча, Хәзрәти Давытның иң матур сүз булган илаһи китапны укыгандагы күркәм тавышы кошларны һәм тәсбих кылып торган тауларны аңа буйсындыра.[142] Шулай ук бу тавыш белән бергә кыргый хайваннар да, хәтта үсемлекләр дә аның тәсбихенә кушыла.[143]

Тавыш, аваз – Аллаһ Җәллә Җәләлүһүнең мәхлукларга бүләк итеп биргән иң зур нигъмәтләреннән берсе ул. Тавыш яралтылмаса, табигатьтә нинди зур бушлык булыр иде. Чөнки тавыш уңай яки тискәре йогынты ясау, җәлеп итү яки этәрү көченә ия бик мөһим сыйфат хасил итә. Тавыш та, башка бик күп нигъмәтләр кебек, хәерле эш өчен дә, явызлык өчен дә коралга әйләнә ала. Икенче яктан караганда, бу галәм һәр сыйфатта хәерле-золымлы, күр-

142. Карагыз: «әл-Әнбия» сүрәсе, 79.
143. Карагыз: «Сәбә» сүрәсе, 10.

кәм-әшәке шикелле ике тарафлы яки ике полюслы булганлыктан, тавышның да матуры яки ямьсезе бар. Сандугач тавышы нәфис җаннарга никадәр рәхәтлек бирер, күңелләргә шатлык тутырыр, ә аның капма-каршысы булган карга тавышы исә шулкадәр тискәре тәэсир калдырыр.

Тавыш кешеләр арасында гына түгел, хайваннар арасында да уңай яки тискәре реакция барлыкка китерә. Урманда бер арысланның үкерүе бөтен зәгыйфь җанварларның котын табан астына төшерә; иң суык хайван булган елан һинд факиренең кәрҗиненнән матур көй ишетеп чыгып, уйный-бии башлый. Чүлләрдән дөяләрнең адымын тизәйтү өчен, бер чара буларак җыр кулланылганы билгеле, аны гарәп музыкасында «һида» дип атыйлар.

Риваятькә күрә, аучылар да, гөнаһсыз нәфис җәйрәннәрне берәр инеш янында нәй[144] тавышы белән алдап чакырып тоталар. Нәйнең татлы тавышын ишеткән җәйрәннәр агач арасыннан чыгып елга читенә килә дә, тезләнеп, һич кымшанмыйча музыканы тыңлый башлый һәм кайнар күз яшьләрен агыза. Яшеренеп көтеп торган аучылар исә, әлеге тиктормас, җитез хайваннарның менә шулай хәрәкәтсез хәленнән файдаланып, аларны бик җиңел эләктереп ала.

Хәтта хайваннарга да әнә шулай тәэсир иткән тавыш алардан бик күп тапкыр камилрәк булуы шиксез адәм баласының хис-тойгыларын нишләтмәс икән?! Әйтик, акча тавышы – материалистларның, су һәм былбыл тавышы – романтикларның, шигъри җаннарның; Коръән белән азанның бөек тавышы исә – күңелен пакьләп, Хак Тәгаләгә юнәлүчеләрнең рәхәтлек чыганагы булып тора. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә, дөнья мәшәкатьләренең җанына өйгән авырлыкларын алып ташлау, күңеленә тынычлык һәм рәхәтлек кертү өчен, кайчак: *«Йә Билал! Бер азан әйт әле, күңелебез ял итсен!..»* – дип әйтә торган була (Әбу Давыт, «Әдәб», 78).

Сандугач сайраганда – каршы таулардан, азан тавышы һаваны ярганда, күк йөзеннән башка бер тавыш та килмәс. Хисчәнлегебез дәрәҗәсенә карап, бу матур тавышларның тәэсирлелеге, үтемлелеге дә шулкадәр көчлерәк булачак.

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ та «Мәснәви»ендә нәйнең көй «телен» тәрҗемә итә. Нәй үзенең кайгы-хәсрәтләрен бәян кыла. Үзен аңламаучыларга ул: «Нәй тавышы ут булды. Аны буш аваз дип санама! Бу ут булмаган җаннар ни кызганыч!..» – дип мөрәҗәгать итә.

Бер нәй остасы: «Сәхәр вакытларында нәемнең тавышы һәм сызланулары аерыла!..» – дип, нәй тавышындагы нәфис һәм хисле авазларны аңлатырга тырыша.

Мухйиддин Гарәби куддисә сирруһ түбәндәгечә аңлатма бирә:

144. Нәй – Шәрык тынлы музыка коралы, флейта, курай төре.

«Бөтен җанлы һәм җансыз мәхлуклар үзенә хас рәвештә Аллаһны зикер кыла. Ләкин аларның бу хәлләре, гамәлләре бер-берсенекеннән аерыла. Җансызлар дөньясы беренче баскычта тора, ягъни таш, туфрак, су, тау токымнары кебек җансыз нәрсәләр галәме Аллаһны иң күп зикер итә, чөнки алар нәфес котыртуыннан һәм ашау-эчү, сулыш алу кебек ихтыяҗлардан азат булганга күрә, гафләттән бик күпкә ерак».

Җәнабел-Хак җансыз нәрсәләрнең мондый уяулыгын аяти кәримәдә түбәндәгечә белдерә:

لَوْ أَنْزَلْنَا هَذَا الْقُرْآنَ عَلَىٰ جَبَلٍ لَرَأَيْتَهُ خَاشِعًا مُتَصَدِّعًا مِنْ
خَشْيَةِ اللَّهِ وَتِلْكَ الْأَمْثَالُ نَضْرِبُهَا لِلنَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَتَفَكَّرُونَ

**«Әгәр дә Без бу Коръәнне бер тауга иңдергән булсак, син аны Аллаһтан куркудан буйсынган хәлдә яргаланганын күрер идең. Бу мисалларны Без кешеләргә фикерләсеннәр дип китерәбез»** («әл-Хәшр», 21).

Аллаһ Тәгалә «Әнбия» сүрәсенең 79 нчы аятендә дә бу хакта телгә ала:

وَسَخَّرْنَا مَعَ دَاوُودَ الْجِبَالَ يُسَبِّحْنَ وَالطَّيْرَ وَكُنَّا فَاعِلِينَ

**«...Тауларны һәм кошларны әмергә (Давытка) буйсындырдык ки, алар тәсбих әйтәләр иде. Без (боларны) кылучылар булдык!».**

Янә Мухйиддин Гарәби хәзрәтләре әйткәнчә, Аллаһны зикер итү мәсьәләсендә гафләттән ераклык ягыннан караганда, җансызлардан соң икенче баскычны үсемлекләр били. Боларының су, һава һәм кояш кебек бер төркем ихтыяҗлары бар. Җансызлардан камилрәк бу мәхлуклар, туфрактан суырып алган төрле химик матдәләрне илаһи ихтыяр белән бер-берсенә кушып, төрле төсле чәчәкләр, яфраклар һәм җимешләр хасил итә. Шунлыктан үсемлекләр, җансыз нәрсәләр белән чагыштырганда, бераз кимрәк зикер кыла. Өченче баскычта хайваннар тора. Аларның тормыш функцияләре үсемлекләрнекеннән камилрәк, катлаулырак. Шуңа күрә ихтыяҗлары күбәйгән, нәфес теләкләре көчлерәк.

Иң ахыргы баскычтагы кешенең исә уңай юнәлештә дә, тискәредә дә офыклары киң. Бу үзенчәлек – иман тәкъдиме нәкъ менә аңа ясалуның табигый бер нәтиҗәсе, ләкин мин-минлек, фантазия, уй-фикерләр һәм дөньяви омтылышлар адәм баласын даими рәвештә гафләткә өстери.

Аяти кәримәдә:

أَلَمْ تَرَ أَنَّ اللَّهَ يَسْجُدُ لَهُ مَنْ فِي السَّمَاوَاتِ وَمَنْ فِي الْأَرْضِ وَالشَّمْسُ وَالْقَمَرُ
وَالنُّجُومُ وَالْجِبَالُ وَالشَّجَرُ وَالدَّوَابُّ وَكَثِيرٌ مِنَ النَّاسِ وَكَثِيرٌ حَقَّ عَلَيْهِ الْعَذَابُ

**«Күкләрдә булганнар, җирдә булганнар, кояш, ай һәм йолдызлар, таулар, агачлар, хайваннар һәм кешеләрдән бик күбесенең Аллаһка сәҗдә кылганнарын күрмәдеңме әллә? Күбесенә исә газап хак булды...»** – дип әйтелә («әл-Хаҗ», 18).

Әлеге аяти кәримә югарыда телгә алынган, дүрт төр мәхлукның сыйфатын, аларның хәл-әхвәленә бәйле рәвештә, шулкадәр күркәм тасвирлаган. Бу аять табигатьтә тәсбих әйтмәгән һичбер җанлы һәм җансыз мәхлук юклыгын раслый.[145] Мәхлуклар арасында иң гафиле, иң аз зикер кыла торганы һәм Хак Тәгаләдән иң ерак торганы дигәндә, кешеләрнең бер өлеше күз алдында тотыла.

Бүтән бер аяти кәримәдә мәхлукларның даими рәвештә Җәнабел-Хакны зикер кылулары менә болай раслана:

تُسَبِّحُ لَهُ السَّمَاوَاتُ السَّبْعُ وَالْأَرْضُ وَمَنْ فِيهِنَّ وَإِنْ مِنْ شَيْءٍ إِلَّا
يُسَبِّحُ بِحَمْدِهِ وَلَكِنْ لَا تَفْقَهُونَ تَسْبِيحَهُمْ إِنَّهُ كَانَ حَلِيمًا غَفُورًا

**«Җиде күкләр белән җир һәм аларда булганнар Аңа тәсбих әйтеп торалар. Аны мактау белән мактамаган һичбер нәрсә юк, ләкин сез аларның тәсбихләрен аңламыйсыз. Һичшиксез, Ул – Мәрхәмәтле (газап бирүдә ашыкмаучы) һәм Гафу итүче»** («әл-Исра», 44).

Ләкин күңел сизгерлеге үскән кешеләр һәр авазда шушы тәсбихне тоя. Хәзрәти Мәүләна бер зәркән кибете каршыннан узганда ишеткән чүкеч тавышы аһәңендәге зикердән транс хәленә кереп, хошуг белән Аллаһны зикергә чумган кебек, алар табигатьтәге гомуми зикер аһәңенә төренеп яшиләр.

Аллаһны зикер итүгә бәйле сер-хикмәтләр галәмендә яшәүче игелекле күңелле бәндәләрнең халәтен шагыйрь Нәҗип Фазыл шигырь юлларында бик матур тасвирлаган:

«Ул ир-егетләр күңел киңлегендә,
Туфракка төренү сагышында!
Йолдызларны тәсбих тартырлар,
Намазда имам артында сафка басарлар!
Эченә нәфес үтеп кергән гыйбадәтләр
Артмасын, дип гел борчуда алар.
Көн башланган һәр сулышта
Мәңгелек кәгазен имзаларга әзер алар...»

145. Зикер һәм тәсбих ике төрле була:
а) Ирексездән зикер. Бу төр зикер мәхлуклар тарафыннан үзеннән-үзе, ихтыярсыздан кылына торган зикер-тәсбихне белдерә. Үсемлекләрнең һәм хайваннарның яшәеше шундый зикер белән бәйле. Бу зикер алар өчен тормыш сулышына тиң диярлек. Зикере беткәннең гомере дә тәмамлана.
б) Ихтыяри зикер. Кешенең үз теләге белән башкарган зикер-тәсбихе.

Табигатьтәге мондый гомуми зикер сыйфатының хәрефләр, хәрәкәләр һәм аваз кебек теркәп-язып куелу мөмкинлеге юк һәм аны һәр колак та ишетә алмый. Әлеге яшерен зикерне бары рухи югарылыкка ирешкәннәр генә ишетергә сәләтле. Юныс Әмрәнең сары чәчәк белән бик бирелеп гәпләшүе әнә шул җөмләдән.

Күңеле һәр мизгелдә зикер белән мәшгуль булган һәм зикер белән берbөтенгә әйләнүне табигый нәрсә хәленә китерә алган затлар бу халәттән соң үзләре ишеткән һәр тавыштагы зикерне аера-тоя беләләр.

Кыскасы, Хак Тәгалә каршында зикер, авазлымы ул, авазсызмы булуга карамастан, тавышларның иң матуры булып тора. Зикер үзенең асыл мәгънәсе белән бергә илаһи китапларга да исем булырлык бай эчтәлекле сүз санала. Әйтик, аяти кәримәләрдә Тәүрат һәм Коръәни-Кәрим «зикер» сүзе белән искә алына. Бу тарафтан караганда, авазлар һәм тавышлар Җәнабел-Хакның Коръәни-Кәримдәге тәүге әмере булган: «Яралтучы Раббың исеме белән укы!» әмеренә ярашлы рәвештә, Коръән моңы белән дә аерым бер зикер хөрмәтенә һәм дәрәҗәсенә ирешә.

Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләре риваять кылына:

«*Коръәнне тавышларыгыз белән бизәгез (аны матур тавышыгыз белән дөрес һәм аһәңле рәвештә укыгыз)!*» (Ибне Мәҗә, «Икамәт», 176).

*«Коръәнне тавышларыгыз белән матурлагыз, чөнки матур тавыш Коръәннең матурлыгын тагын да арттырыр»* (Дарими, «Фәдаилүл-Куръан», 34).

Башка бер риваятьтә Пәйгамбәр Әфәндебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең: *«Коръәнне тәганнисез (көйсез) укыган бездән түгел»*, – дигән сүзләре тапшырыла (Бохари, «Тәүхид», 44; Әбу Давыт, «Витр», 20). Бу хәдис-шәрифтәге «тәганни» сүзенең «матур тавыш» мәгънәсендә кулланылуын белдергән галимнәр тавышы матур булмаган кешеләрнең дә хәлләреннән килгәнчә матуррак укырга тырышырга тиешлекләрен ассызыклый. Чөнки сүзләрнең иң матуры Коръәни-Кәрим булганлыктан, кешегә хас тавышның күркәмлеге һәм зиннәтлелеге Коръән моңы аша ачылыр.

Һәр матур тавыш күпмедер вакыттан соң ялкытыр, ләкин Коръән авазлары һичкайчан туйдырмас!.. Чөнки аның бөек аһәңен тою насыйп булган күңелләргә бу авазлар чын-чынлап җәннәтнең хуш исләрен алып килер.

Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди:

*«Аллаһ Тәгалә матур тавышлы пәйгамбәренең Коръәнне яңгыравык тавыш белән көйләп укуыннан да ныграк һичнәрсәдән хушланмагандыр»* (Бохари, «Фәдаилүл-Куръан» 19; «Тәүхид», 32; Мөслим, «Мүсафирин», 232–234).

Хәдис-шәрифләр безгә Коръән кыйраәтендә тәртил һәм тәҗвиднең никадәр мөһим икәнлеген күрсәтә.

Үкенеп тәүбә итүчеләрнең һәм гомер буе интегеп яшәүчеләрнең күңел тынычлыгы да Коръән аһәңнәренең җаннарны айкарлык дәвасында яшеренгән. Мәңгелек котылу юлын эзләүчеләр аның җаннарга гомер биргән җәннәт телен өйрәнүгә мохтаҗ. Ләкин Коръән тавышына һәм аһәңенә күңел салмаган гафил бәндәләр тормышның тышкы тарафын гына белә ала, эчке, асыл галәмнең хикмәт һәм хакыйкатьләреннән мәхрүм калалар. Алар гомер буе дөнья ләззәтләре һәм шәһвәтләре артыннан куа, ләкин җиһанның яратылыш хикмәтенә карата ваемсызлыктан арына алмыйлар. Алар бу дөнья табыныннан убырларча ашый-эчә, тик мәҗлеснең чын хуҗасы булган «Рәззак»ны танымыйлар.

Алар каберләргә якыннарын җирлиләр, тик туфрак астындагы олуг маҗаралардан хәбәрләре юк. Алар агачларның авазсыз-сүзсез телен аңламыйлар. Зилзилә, давыл һәм башка төрле авырлыклар белән кисәтүле сынауларны узганда да, хакыйкатьләргә арт белән борылалар, «табигый афәтләр» дип зарланып, ялган, уйдырма юанычларга сыенып, качар тишек эзлиләр. Ни гаҗәп, илаһи мөлкәт эчендә яшәп тә, ул мал-мөлкәтнең чын хуҗасына дошманлык юлына басалар.

Йөрәге Коръән нуры белән яктыртылган мөэминнәр исә бөек хикмәтләр турында фикерли. Алар укыган илаһи кәлам күңелләренә гүя: «Син – Аллаһ колы, Аның милегендә яшисең! Ул биргән ризыклар белән туклanasың. Коръәннең хикмәт-серләренә чум да, Раббыңа сәламәт йөрәк белән сәфәр чык!..» – дип нәсыйхәт әйтә.

Коръәннең илаһи нәсыйхәтенә күңел бирүчеләр һәрдаим Җәнабел-Хакка гыйбадәт кылу уенда йөри. Алар үзләренә бирелгән нигъмәтләргә шөкер итә һәм фани гомерләрен мәңгелек тормышларының нигез капиталына әйләндерергә тырышып яшиләр. Шуңа күрә Коръән Мөхәммәд рухыннан бер өлешкә ия була алганнар өчен җирләр-күкләр телен, бәрәкәт һәм фазыйләт хәзинәсен тәшкил итә.

Хәзрәти Пәйгамбәр һәм Коръәни-Кәрим – Аллаһ Тәгаләнең үз колларына насыйп иткән ике олуг нур чыганагы ул.

Аллаһның сыйфатлары тулысынча чагылыш тапкан өч нәрсә бар – галәм, Коръән һәм кеше.

Галәм, дөнья – илаһи сыйфатларның практик чагылышы, күренеше; Коръән – сүздәге чагылышы, кеше исә асыл килеш-килбәтендә бөтен күренешләрнең тупланмасы. Кешесез дөнья никадәр утсыз, караңгы булса, Коръәнсез бер кеше дә нәкъ әнә шундый.

Пәйгамбәр Әфәндебез: *«Йөрәгендә бер микъдар да Коръән булмаган зат җимерек бер өй шикелле»*, – дип юкка гына әйтмәгән (Тирмизи, «Фәдаилүл-Куръан», 18; Дарими, «Фәдаилүл-Куръан», 1).

Галәм – тавышсыз Коръән, ә Коръән исә – тавышлы бер дөнья ул. Кешене исә, илаһи серләрнең бер чагылышы буларак, боларның төше һәм асылы дип атарга мөмкин. Коръән бер сөйләм могҗизасын хасил итә һәм Хак Тәгаләнең нотыгы булып тора. Коръән хакыйкатьләреннән ерак җан исә эченә сумала яугандай караңгы, нурсыз һәм ике дөнья кабахәте булыр.

Коръәни-Кәримнең хисапсыз хикмәт һәм бәрәкәтләреннән берничәсен искә алып үтик:

Коръән кешегә тышкы дөньядагы матурлык, нәфислек һәм кодрәт чагылышын күрсәтеп, аның эчке дөньясын уятыр. Бәндәгә шушы матур табигатькә карата хисле, сизгер йөрәк бирер, курку тойгысы салыр. Аллаһ һәм Рәсүленең мәхәббәт мохитенә кертер. Ике дөнья бәхетенең юламаны булган Коръәни-Кәрим үзенә сыенучының тормышын иң югары дәрәҗәдә тәртипкә салып, аны тыныч, баланслы гомернең бәхет бакчасына алып килер.

Галәм һәм андагы һәр кисәкчек искиткеч баланс законына буйсына икән, Коръәнгә сарылмыйча, иң төп нигезен һәм тигезлеген югалткан кеше үзен түбәнчелеккә төшерә һәм хәсрәт чокырларына тәгәрәтә, чөнки бәндәнең рух һәм бәдәнендәге үлчәмнәр һәм баланс Коръәни-Кәрим бәрәкәтенең бер нәтиҗәсе, чагылышы булып тора.

Сәламәт йөрәкле кеше өчен Коръәни-Кәрим тирән фикер дәрьясын хасил итә. Һәр гакыллы зат өчен вакыт һәм урынга бәйле рәвештә илаһи хакимлек турында уйлану һәм хикмәт тулы кыйссалардан сабак алып, камиллеккә ирешә алу шарт, бу исә – бары Коръәни-Кәрим рәхмәтенең чагылышы гына.

Күзгә күренмәс һәм танып беленмәс мең дә бер галәмнең серләр картасын күз алдына җәеп салып, яшерен галәмнең офыкларыннан хакыйкать нурларын чәчүе дә – янә Коръәнгә генә хас бер серле күренеш.

Коръәни-Кәрим – кешене дөреслеккә, күркәм әхлакка, гыйбадәткә, гыйлемгә, ахирәт бәхетенә өндәгән үгет-нәсыйхәтләр тупланмасы ул. Шунысы да бар: аларны Раббың насыйп иткән зирәклек бәрабәренә генә тиешле дәрәҗәдә аңларга мөмкин.

Коръән бөтен кешелекне һидәяткә, тугры юлга өнди. Тере Коръән тәфсиренә тиңләрлек тормышы белән Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез исә һидәяткә юл күрсәтүче булып тора. Ягъни Коръәни-Кәрим һәм Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм, бер яктан караганда, кешелекнең инкяр һәм ваемсызлык чирләренә бердәнбер шифа чыганагын тәшкил иткән бик зур бер даруханәгә тиң. Шунлыктан кыямәт купканчы бу дөньяга киләчәк соңгы бәндәгә кадәр барлык кешелек тә Мөхәммәд

өммәтеннән санала. Аларның бер өлеше – Аның бөек чакыруына буйсынучылар – «өммәти иҗабә» (иярүчеләр өммәте) дип атала, Мөхәммәд өммәтенең нигезен әнә шулар тәшкил итә. Бүтәннәрне исә «өммәти гайре иҗабә» дип атыйлар.

Бөтен кешелекнең бәхет һәм иминлек чыганагы Коръән белән хисләнеп, аның бәрәкәтле мохитенә чума алуга, аның хөкемнәре белән гамәл кылуга һәм аның әхлагы белән әдәп-әхлагыңны камилләштерүгә бәйле. Шул рәвешле Коръәннән ерак бер гомер мәңгелек бәхетсезлек дигән сүз була.

Җан, яшәү, үлем, терелү, ахирәт һәм мәңгелек кебек бәндә акылын гаҗизлектә калдырган иң катлаулы төшенчәләр, табышмаклар иң тәэсирле һәм иң үтемле рәвештә бары Коръәни-Кәрим белән генә чишелеш табар.

Аллаһның чиксез гыйлеменең һәм кәламенең бер гәүдәләнеше булган Коръәндә сүз белән аңлатып бирелә алмаслык тиңсез ышанычлылык, вөҗдан тынычлыгы һәм үзара бәйләнеш бар. Тарих шуңа шаһит: илаһи дәгъват утын күтәреп барган пәйгамбәрләрдән һәркайсы, үзеннән әүвәлгеләрнең юлын раслап, аларның хезмәтен ныгыта, үстерә, ә философлар акылны тупикка илтә торган юлларда йөргәнгә һәм дөреслектән читкә тайпылган фәлсәфәләренең чоңгылларына батканга, һәрвакыт әүвәлгеләрне ялганда, хаталануда гаепләгән. Яшәешне һәм галәмнең чиксез мәгънәсен төшенү максатында кешелек тарихы дәвамында акылның чикле мөмкинлекләре кысаларында үстерелгән фәннәрдә төрледән-төрле каршылыклар тулып ята.

Шул сәбәпле Коръәни-Кәрим белән сугарылган мөэминнәрнең күңелләре илаһи хакыйкатьләрнең бер хәзинәсенә әйләнсә, философларның гаҗиз аң-акыллары белән формалаштырган бәндәчел караш-фикерләренә иярүчеләр исә караңгылыкта капшанып юл табарга маташучы мәңге фәкыйрь мескеннәр хәлендә кала. Димәк, чын тормыш Коръән хакыйкатьләре хөкемендә яшәүдән гыйбарәт.

Беркөнне Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез: *«Йөрәкләр тимер кебек тутыгыр»*, – дип белдерә. Шуннан соң: «Аны ни ялтыратыр, йә, Аллаһның Рәсүле?» – дип сорагач: *«Аллаһның китабын күп-күп уку һәм Аллаһны күп-күп зикер итү»*, – дип җавап бирә (Гали әл-Мүттакый, «Кәнзүл-Уммал», II, 241).

Янә Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең: *«Күзләрегезгә гыйбадәттән өлеш бирегез!»* – дигән нәсыйхәтен ишеткәч, әсхабе кирам: «Күзләребезнең өлеше нинди, йә, Аллаһның Рәсүле?» – дип сорый. Пәйгамбәр Әфәндебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Мусхафка (Коръәнгә) карау, аның эчендәгеләр турында уйлану һәм эчтәлегеннән гыйбрәт алу»*, – дип ачыклый (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», I, 39).

Аллаһ Тәгалә мәңгелек уңышка лаеклы бәхетле колларын искә алганда, беренче чиратта, күп итеп Коръән укучыларны санап китә. Аяти кәримәләрдә болай диелә:

إِنَّ الَّذِينَ يَتْلُونَ كِتَابَ اللهِ وَأَقَامُوا الصَّلَاةَ وَأَنْفَقُوا مِمَّا رَزَقْنَاهُمْ سِرًّا وَعَلَانِيَةً يَرْجُونَ تِجَارَةً لَنْ تَبُورَ لِيُوَفِّيَهُمْ أُجُورَهُمْ وَيَزِيدَهُمْ مِنْ فَضْلِهِ إِنَّهُ غَفُورٌ شَكُورٌ

**«Һичшиксез, Аллаһның Китабын укыганнар, намаз укыганнар һәм Без аларның ризыкландырган нәрсәләрдән (Аллаһ өчен) яшерен яки ачык сарыф иткән кешеләр сәүдәгә өмет итәләр ки, ул зарар китерә торган булмаячак. Ул (Аллаһ) аларга әҗерләрен тутырып бирер һәм фазылыннан аларга өстәр өчен. Һичшиксез, Ул – Гафу итүче, Савап бирүче»** («Фатыйр», 29–30).

مِنْ أَهْلِ الْكِتَابِ أُمَّةٌ قَائِمَةٌ يَتْلُونَ آيَاتِ اللهِ آنَاءَ اللَّيْلِ وَهُمْ يَسْجُدُونَ

**«…Аларда төннәрен Аллаһның аятьләрен укый торган һәм сәҗдә кыла торган истикамәтле (турылыклы) бер җәмәгать бар»** («Әли Гыймран», 113).

Аллаһның аятьләрен уку иманны арттыра. Моны түбәндәге тагын бер аяти кәримә раслый:

إِنَّمَا الْمُؤْمِنُونَ الَّذِينَ إِذَا ذُكِرَ اللهُ وَجِلَتْ قُلُوبُهُمْ وَإِذَا تُلِيَتْ عَلَيْهِمْ آيَاتُهُ زَادَتْهُمْ إِيمَانًا وَعَلَىٰ رَبِّهِمْ يَتَوَكَّلُونَ

**«Иманучылар – Аллаһ искә алынган чакта йөрәкләре курку белән тулучылар, аларга Аның аятьләре укылган чакта, аларның иманнарын арттырыр, һәм алар Раббыларына гына тәвәккәл итәрләр»** («әл-Әнфәл», 2).

Аллаһның сүзләрен уку, һичшиксез, гыйбадәтләр арасында иң фазыйләтлеләрдән. Димәк, Коръәнне иң күркәм рәвештә кыйраәт кылу иң мөһим бурычларыбызның берсе булып тора. Аллаһ Тәгалә:

وَرَتِّلِ الْقُرْآنَ تَرْتِيلًا

**«...Коръәнне тәртил белән (әкрен-әкрен) укы!»** – дип боера («әл-Мүззәммил», 4).

Башка яктан караганда, Коръәни-Кәрим уку белән бергә аны дәшми-нитми генә тыңлау да бик мөһим. Шул дәрәҗәдә ки, Коръән уку – сөннәт, тыңлау исә фарыз гамәл санала. Аяти кәримәдә анык әйтелә:

وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَأَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез рәхмәт ителерсез!»** («әл-Әгъраф», 204).

Намаз эчендә булсынмы, намаздан тышмы – Коръән укыганда, аның мәгънәләрен дөрес аңлау, үгет-нәсыйхәтләреннән файдалану һәм эш-гамәлләреңне шуларга карап көйләү өчен, бөтен игътибарны Изге Китапка бирү һәм дәшми-сөйләшми тору зарур. Чөнки сөйләшмәү яхшылап тыңлауга, яхшылап тыңлау сизгерлеккә, алдан күрүчәнлеккә, сизгерлек иман һәм гамәлгә, иман һәм гамәл исә илаһи рәхмәт һәм нигъмәткә сәбәп, нигез була.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Коръәни-Кәримне башкалар укыганда тыңларга ярата, хәтта кайчак Ибне Мәсгуд радыйаллаһу ганһегә укырга кушып, аны эчтән бик шатланып тыңлый торган була. Бервакыт Ибне Мәсгуднең Коръән укыганын тыңлаганда, Рәсүлүллаһның мөбарәк күзләре яшьләнә.

Әлеге вакыйганы Габдуллаһ ибне Мәсгуд радыйаллаһу ганһе болай бәян кыла:

Бервакыт Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм миңа: *«Әй, Ибне Мәсгуд! Миңа Коръән укы!»* – дип боерды. Мин исә: «Йә, Рәсүлүллаһ! Коръән Сиңа җибәрелгән булгач, ничек инде аны Сиңа укый алыйм?» – дидем. Шуннан соң Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Мин Коръәнне башкалардан тыңларга да яратам»*, – дип әйтте.

Мин «Ниса» сүрәсен укый башладым.

فَكَيْفَ إِذَا جِئْنَا مِنْ كُلِّ أُمَّةٍ بِشَهِيدٍ وَجِئْنَا بِكَ عَلَىٰ هَؤُلَاءِ شَهِيدًا

**«"Без һәр өммәттән бер шаһит китергәч, сине дә шуларга бер шаһит буларак китергәч, (хәлләре) ничек булачак!"** – диелгән аяти кәримәгә («ән-Ниса», 41) җиткәч, Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *"Җитәр!"* – дип белдерде. Шулчак, Рәсүлүллаһның күзләреннән яшь акканын күрдем» (Бохари, «Тәфсир», 4/9; Мөслим, «Мүсафирин», 247).

Икенче бер хәдис-шәриф тә бар:

Берзаман Үсәйд ибне Худайр радыйаллаһу ганһе төнлә «Бәкара» яки «Кәһф» сүрәсен матур тавыш белән тәфсилләп укый. Аты янәшәсендә бәйләнгән була. Үсәйд Коръән укыганда ат өркә башлый. Үсәйд туктап кала; ат та тынычлана. Кабат укый башлауга ат янә өркеп, арт аякларына баса. Үсәйд туктый, ат кабат тынычлана. Үсәйд тагын укырга керешкәч, ат янә котырына. Шуннан соң Үсәйд укудан баш тарта. Улы Яхъя атка якын бер җирдә яткан була. Ат балага берәр зыян салмасын өчен, Үсәйд улы Яхъяны үзенә таба

тарта. Шулвакыт башын өскә күтәреп карагач, ак болыт күләгәсенә охшаган томан эчендә шәмнәр шикелле ниндидер нәрсәләрнең ялтырап яктыртканын күреп ала. Иртән бу хәлләрне ул Рәсүлүллаһка сөйләп бирә. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа: *«Укы, әй, Худайр углы, укы, әй, Худайр углы!»* – дип боера.

Үсәйд ибне Худайр радыйаллаһу ганһе: «Йә, Аллаһның Рәсүле! Атның Яхъяны таптап изүеннән курыктым, чөнки бала атка якын ята иде. Шулчак башымны югары күтәреп карагач, күктә болыт шәүләсе кебек аклык эчендә шәмнәр кебек нәрсәләрнең яктыртканын күрдем. Соңыннан алар күккә күтәрелеп киттеләр», – дип сөйли.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «*Әй, Үсәйд! Аларның кем икәнен беләсеңме?»* – дип сорый.

Үсәйд: «Юк!» – дип җавап биргәч, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Әй, Үсәйд! Алар фәрештәләр иде; синең тавышыңа җыелганнар. Әгәр Коръән укуны дәвам итсәң, таңга кадәр сине тыңларлар иде. Аларны кешеләр дә күрер, халык күзеннән качмаслар иде...»* – дип аңлата (Бохари, «Фәдаилүл-Куръан», 15; Мөслим, «Мүсафирин», 240–243).

Хәдис-шәрифтә Коръәни-Кәрим моңының фәрештәләрне, хәтта хайваннарны да хисләндергәнлеге белдерелә. Шулай булгач, Коръәни-Кәрим кер-пычрактан арынган, яктылыкка күмелгән йөрәккә никадәр серләрне ачып бирә ала икән?

Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе кичергән халәт тә уйланырга мәҗбүр итә. Аның: «Бәкара» сүрәсен уникe елда укып чыктым һәм шуңа шөкер итеп бер дөяне корбан чалдым!..» – дип әйткәне риваять кылына (Куртуби, «Тәфсир», I, 40). Аның Коръән укуы авазларны яңгыратудан гына гыйбарәт уку булмый. Сүз Коръәни-Кәримнең хикмәт һәм серләрен аңлап, үзләштереп, андагы илаһи метафораларны төшенеп, шуларны кулланып яши-яши уку турында бара. Коръәнне чын мәгънәсендә уку һәм аннан тиешенчә файдалану бары әнә шул рәвешле генә чынга аша ала.

Коръәни-Кәримне әнә шундый югары сыйфатта уку белән бәйле түбәндәге мисал да бик гыйбрәтле:

Әбү Бәкер Вәррак Хәзрәтләренең кечкенә улы була. Коръәни-Кәримне өйрәнер өчен, ул остаздан дәрес ала. Беркөнне мәктәптән башка вакыттагыдан иртәрәк, йөзе саргайган кыяфәттә, калтырый-калтырый кайтып керә. Әбү Бәкер Вәррак Хәзрәтләре бу хәлгә гаҗәпләнеп, улыннан: «И улым, ни булды? Ник мәктәптән болай иртә кайттың?» – дип сорый.

Нәни йөрәгенә кереп утырган Аллаһтан курку хисе аркасында көзге яфрактай саргайган йөз белән улы: «Әткәем! Бүген укытучыбыз миңа Коръәннән бер аять өйрәтте, аның мәгънәсен аңлагач, куркуымнан шушы хәлгә

төштем!» – дип сөйләп бирә. Бу юлы атасы: «Улым, ул кайсы аяти кәримә соң?» – дип кызыксына. Сабый укый башлый:

فَكَيْفَ تَتَّقُونَ إِنْ كَفَرْتُمْ يَوْمًا يَجْعَلُ الْوِلْدَانَ شِيبًا

**«Әгәр дә кяфер булсагыз, балаларны чал чәчле (карт кебек) итәчәк көннән ничек котылырсыз?»** («әл-Мүззәммил», 17).

Соңыннан сабый, бу аятьнең дәһшәт һәм бөеклегеннән чиргә сабышып, үлем түшәгенә егыла һәм озак та тормый җан тәслим кыла. Әтисе Әбү Бәкер Вәррак бу вакыйгадан бик тәэсирләнә, улының каберенә бик еш барып йөри һәм елый-елый, үзалдына болай дип сөйләнә: «И, Әбү Бәкер! Улың Коръәннән бер аять өйрәнде дә Аллаһтан курку аркасында җан тәслим кылды. Син исә инде күпме вакыт Коръәни-Кәрим укыйсың, ә илаһи хөкемнән әле һаман бер бала кадәр дә курыкмыйсың!»

Коръәни-Кәрим – мәрхәмәтле йөрәкләрне әнә шулай тетрәндерерлек серләр-хикмәтләр океаны ул. Менә бу аяти кәримә Коръәннең рухи үлчәменең чиксезлеген, шул рәвешле Җәнабел-Хак гыйлеменең, Аның бөеклек һәм хакимлегенең очсыз-кырыйсызлыгын шулкадәр анык чагылдыра:

وَلَوْ أَنَّمَا فِي الْأَرْضِ مِنْ شَجَرَةٍ أَقْلَامٌ وَالْبَحْرُ يَمُدُّهُ مِنْ بَعْدِهِ
سَبْعَةُ أَبْحُرٍ مَا نَفِدَتْ كَلِمَاتُ اللَّهِ إِنَّ اللَّهَ عَزِيزٌ حَكِيمٌ

**«Әгәр дә җирдәге һәрбер агач каләмнәр булса, ул диңгез исә (язу карасы булып) артыннан тагын җиде диңгез аның карасын арттырса, Аллаһның сүзләре (язылып) бетмәс иде, чөнки, һичшиксез, Аллаһ – Бөек, Хикмәт иясе»** («Локман», 27).

Кеше дә бу дәрьядан йөрәгенең хәленнән килгән хәтле үзенә насыйп өлеш ала, ләкин ул да әле диңгездән бер кырмыска алган кадәр генә микъдарга тиң. Шагыйрь шушы хакыйкатьне болай дип сурәтли:

«Бер җәүһәр диңгезе эченә чумдым,
Хәлемнән килгәнчә алдым.
Тик бер тамчыдыр бөтен алганым,
Диңгез һаман калды туп-тулып».

Кыскасы, бу болында кешене гаҗизлек, көчсезлек көтә... Бердәнбер чара Аллаһның рәхмәтенә сыенудан гыйбарәт!..

Түбәндәге хәдис-шәрифнең мәгънәсе нинди тирән:

«Кем үзен (нәфесен) таныса, шул дәрәҗәдә Раббыны таныган булыр» (Аҗлуни, «Кәшфүл-Хафа», II, 361).

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ: «Коръәни-Кәримнең тышкы күренешен берникадәр кара белән язарга мөмкин. Серләренә исә чиксез дәрьялар, ярсыз-кырыйсыз диңгезләр җитмәс!..» – дип әйткән. Димәк, чын Коръән әһеле аны уку белән җанына ләззәт ала, аның хөкемнәре белән яши, аның әхлагы белән әхлагын яхшырта һәм аның хикмәте белән бар булмышын камилләштерә. Мондый сыйфатларга ия Коръән әһеле турында туфракка аның җәсәден ашамаска боерылачак.

Аллаһ дусларыннан Мәхмүд Сами Рамазаноглу куддисә сирруһ Аданада шул сыйфатларга ия хәлдә җан тәслим кылган бер хафизның, юл төзелеше сәбәпле, утыз елдан соң каберен ачарга туры килгәнлеген, тик бу изге бәндәнең җәсәденең һич бозылмаганлыгын, өстәвенә хәтта кәфененең ялтырап торганлыгын шәхсән үзе күргән шаһит буларак сөйләп калдырган.

Барлык пәйгамбәрләр кебек Аллаһның китабын укып, дәгъват кылуда вазифалы булган Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез бер хәдис-шәрифендә: *«Сезнең иң хәерлегез – Коръәнне өйрәнүче һәм өйрәтүчегездер»*, – дип әйткән (Бохари, «Фәдаилүл-Куръан», 21).

Чөнки Коръәни-Кәрим – Аллаһның кешелеккә Үз катыннан җибәргән иң зур бүләгеннән гыйбарәт бөек кәлам, бөек сүз. Бу уңайдан Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең: *«Аллаһ кәламенең Ул яралтканнарның сүзләреннән өстенлеге Аллаһның коллары каршында өстенлеге кебек»*, – дигән хәдисе тапшырыла (Дарими, «Фәдаилүл-Куръан», 6). Ягъни Коръәни-Кәрим адәм баласы сүзләре белән чагыштырып булмаслык дәрәҗәдә тиңсез һәм иксез-чиксез. Ләкин илаһи кәламне уяу йөрәк белән уку тиеш, чөнки Коръәни-Кәрим үзен укучының күңел халәтенә бәйле рәвештә ачыла.

Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

*«Коръән укучы мөэмин әфлисун җимеше кебек, исе дә хуш, тәме дә тәмле. Коръән укымаучы мөэмин хөрмә кебек, исе юк, ләкин тәме хуш. Коръән укучы монафыйк рәйханга охшар, исе хуш, ә тәме ачы. Коръән укымаучы монафыйк Әбү Җәһил карбызына[146] охшар, исе дә юк, тәме дә ачы»* (Бохари, «Әтгыймә», 30; «Фәдаилүл-Куръан» 17, 36; Мөслим, «Мүсафирин» 243).

Башка бер хәдис-шәрифтә Коръәнне ваемсызлык белән, гафил хәлдә укучылар турында: *«Алар Коръән укырлар, (тик укыганнары) бугазларыннан аска узмас!»* – дип әйтелә (Бохари, «Фәдаилүл-Куръан», 36).

Димәк, фикерләмичә генә укылган Коръәни-Кәримнән бернинди дә бәрәкәт иңмәс. Мондый кыйраәт аны башкаручыны җәһәннәм утына гына сөйри. Коръәнне шул рәвешле укыган бәндәләр турында Җәнабел-Хак:

أَفَلَا يَتَدَبَّرُونَ الْقُرْآنَ أَمْ عَلَىٰ قُلُوبٍ أَقْفَالُهَا

146. Әбү Җаһил карбызы – колоквинт үсемлеге.

**«Алар Коръән турында һич уйламыйлармы? Әллә (аларның) йөрәкләрендә йозаклар бармы?»** – дип әйтә. (Мөхәммәд, 24).

Тирән һәм сизгер фикерләү сәләтенә ия киң күңелле бәндәләр мондый кисәтүдән бик зур гыйбрәт ала. Уйлап карагыз әле, Коръәни-Кәримнең:

رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

**«...И, Раббыбыз! Син моны юкка яралтмадың. Син пакьсең! Безне Ут газабыннан сакла!»** аяти кәримәсе иңгәч («Әли Гыймран», 191), Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм күкләрнең йолдызларны кызыктырырлык энҗе бөртеге шикелле күз яшьләре белән таң атканчы елаган.

Табигыйннәрдән Гата ибне Әби Рәбаһ рәхмәтуллаһи галәйһи истәлеге:

Хәзрәти Гайшәгә: «Аллаһ Рәсүленең син күргән, сине иң гаҗәпләндергән эш-гамәле турында миңа сөйли алмыйсыңмы?» – дидем. Гайшә анабыз: «Аның нинди хәле гаҗәпләндерми калган микән! – диде һәм сүзен дәвам итте. – Бер төнне яныма килеп ятты да күпмедер вакыттан соң: *“Рөхсәт итсәң, торып, Раббыма гыйбадәт кылыйм”*, – диде. Мин исә: “Валлаһи, Синең белән бергә булырга телим, ләкин Сине сөендергән нәрсәне ныграк яратам”, – дидем.

Шуннан соң Ул торды, тәһарәтләнде, аннары намазга басты һәм елый башлады. Шулкадәр елады ки, күз яшьләре күкрәген чылатты. Соңыннан рөкугъка китте, янә елаудан туктамады. Аннары сәҗдәгә капланды, сәҗдәдә чакта да елады, аннары сәҗдәдән башын күтәрде һәм тагын елады. Бу хәл нәкъ Билал радыйаллаһу ганһе килеп, иртәнге азанны әйткәнче дәвам итте. Хәбиби Әкрәмнең елавын күргәч, Хәзрәти Билал радыйаллаһу ганһе: “И, Аллаһның Рәсүле, узган һәм киләчәк бөтен гөнаһларыгыз ярлыканган килеш Сине ни-нәрсә елатты?” – дип сорады.

Пәйгамбәребез: *“Аллаһка бик күп шөкер итүче кол була алмыйм микән? Валлаһи, бу төндә миңа шундый аять иңдерелде, аны укып та, бу хакта фикер йөртмәгәннәргә ни үкенеч булсын!”* – диде һәм менә бу аяти кәримәләрне укыды»:

إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ لَآيَاتٍ لِأُولِي الْأَلْبَابِ
الَّذِينَ يَذْكُرُونَ اللَّهَ قِيَامًا وَقُعُودًاوَعَلَىٰ جُنُوبِهِمْ وَيَتَفَكَّرُونَ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ
وَالْأَرْضِ رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

**«Һичшиксез, күкләрнең һәм җирнең яралтылуында, төн белән көннең бер-берсен алыштыруында акыл ияләре өчен (Аллаһның бердәнберлеген күрсәтә торган) билгеләр бар. Алар аякта торганда да, утырган килеш тә, янтыкларында килеш тә Аллаһны зикер итәләр һәм күкләр белән җир-**

**нең яратылышы турында фикерлиләр: “И, Раббыбыз! Син моны юкка яралтмадың. Син (һәртөрле кимчелекле сыйфатлардан) пакьсең! Безне җәһәннәм газабыннан сакла!” (дип ялварырлар)»** («Әли Гыймран», 190–191)» (Ибне Хиббан, II, 386).

Шунлыктан мөэминнәрнең Аллаһтан куркып түккән күз яшьләре фани төннәрнең зиннәтенә, кабер караңгылыкларының йолдызларына, җәннәт бакчаларының чык тамчыларына тиң. Җәнабел-Хак барыбызны да Коръәни-Кәримнең сер-хикмәтләре каршында хисләнмәгән йөрәктән һәм яшьләнмәгән күздән сакласын!

Кыскасы, Коръәни-Кәримне уку белән генә канәгатьләнмичә, аннан да бигрәк аның әдәп-әхлагы белән әхлагыбызны яхшыртырга, хөкемнәре белән яшәргә тырышырга тиешбез. Чөнки Коръәннән файдалануның чын бәрәкәте әнә шунда. Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезнең сәхабәләренә һәм шул рәвешле безгә дә дәресе шушы юнәлешне күздә тота.

Әбү Габдеррахман әс-Сүләми болай дип искә ала:

«Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләреннән безгә Коръәни-Кәрим өйрәтә торган бер зат бар иде. Ул безгә болай диде: ”Без Пәйгамбәр Әфәндебездән ун аять ала идек, бу аятьләрдәге мәгълүматларны һәм гамәлләрне үзләштермичә торып, чираттагы ун аятькә күчми идек. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм безгә гыйлемне дә, гамәлне дә бергә өйрәтә иде”» (Ибне Ханбәл, V, 410; Хәйсәми, I, 165).

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ «Мәснәви»еннән:

«Коръәни-Кәрим – пәйгамбәрләрнең эш-гамәлләре һәм сыйфатлары ул. Коръәни-Кәримне хошуг белән укып, шуның белән яшәсәң, үзеңне пәйгамбәрләр белән очрашкан дип сана! Пәйгамбәрләрнең кыйссаларын укыгач, тән читлеге җан кошына тар тоела башлар!»

«Без бу тән читлегеннән бары шушы чара ярдәмендә генә котылдык. Ул читлектән иреккә чыгу өчен шушы ысулдан, ягъни тәүхид юлыннан барудан башка чара юк!»

Йә, Раббы! Йөрәкләребезне Коръәни-Кәрим нурыннан һәм Хәбибеңнең мәхәббәтеннән аерма! Амин!..

*Хәзрәти Давыт галәйһис-сәләәм*





ХӘЗРӘТИ

# Сөләйман

*галәйһиссәләм*

### *Галәмәт зур дөнья байлыгына һәм аны ирекле куллануга йөрәгендә урын бирмәгән*

# ХӘЗРӘТИ СӨЛӘЙМАН

### *галәйһис-сәләәм*

Сөләйман галәйһис-сәләәм Газзәдә туа. Атасы Давыт галәйһис-сәләәм үлгәндә, аңа 12–13 яшьләр була. Атасы кебек ул да башта хөкемдар, соңыннан пәйгамбәр вазифасын башкара. Җиде елда Бәйтүл-Макдисне («әл-Әкъса» мәчетен) төзи. Йәмәндәге Сәбә патшабикәсе Бәлкис белән өйләнешә. Иерусалимдә бакыйлыкка күчә.

Сөләйман галәйһис-сәләәм балачагыннан бирле тиз отып алучан, бик зирәк була. Аның бу сыйфаты белән бәйле рәвештә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм мондый бер вакыйга турында бәян кыла:

*«...Шул заманнарда ике хатын һәм аларның ике улы яшәгән. Юлда барган вакытта бер бүре килеп чыгып, хатыннарның өлкәнрәгенең баласын күтәреп китә. Шуннан соң бу хатын иптәшенә (кечерәк яшьтәге хатынга): «Бүре синең балаңны алып китте», – дип әйтә. Теге хатын: «Юк, ул синең балаңны алып китте бит!» – дип каршы килә.*

*Ахыр чиктә бу ике хатын, бәхәсне хөкем кылсын өчен, Давыт галәйһис-сәләәмгә мөрәҗәгать итәләр. Давыт галәйһис-сәләәм бала өлкәнрәк хатынныкы булырга тиеш, дип хөкем чыгара. Теге хатыннар, мәхкәмәдән чыккач, Давыт галәйһис-сәләәмнең улы Сөләйман галәйһис-сәләәм янына юнәлә. Аңа Давыт галәйһис-сәләәм чыгарган хөкем турында сөйләп бирәләр. Сөләйман галәйһис-сәләәм исә: «Миңа бер пычак алып килегез! Баланы бу ике хатын арасында бүлим!» – ди.*

*Шуннан соң хатыннарның яшьрәге: «Юк, юк, берүк алай эшләмә! Сиңа Аллаһның рәхмәте булсын! Бала бу хатынныкы!» – дигән. Бу сүзләрдән соң Сөләйман галәйһис-сәләәм баланың яшьрәк хатынныкы булуы турында хөкем чыгарды»* (Бохари, «Әнбия», 40). Чөнки ана кешегә хас шәфкать-мәрхәмәт баланың үлеме белән ризалаша алмый.

Сөләйман галәйһис-сәләәмнең зирәклеге белән бәйле тагын бер риваять менә мондый:

Бер төндә сарык көтүе басуга кереп, анда үскән нәрсәләрне ашап-изеп бетерә. Басу хуҗалары Давыт галәйһис-сәләәмгә килеп, шикаять белдерә. Зыян күргән басу бәясе ягыннан сарык көтүе кадәр тора. Шунлыктан Давыт галәйһис-сәләәм сарыкларның басу хуҗасына бирелергә тиешлеге турында

хөкем чыгара. Сөләйман галәйһис-сәләәм ул вакытта әле кечкенә булуына карамастан: «Әтием, тагын бер чишү юлы бар! Сарыкларны басу хуҗасына бурычка бирик; сөтеннән-йонынннан файда күрсен. Шулвакытта басуны аякка бастырсын. Басу элекке хәленә кайтканчы, сарыклар аңарда калсын. Эшләре кабат җайга салынгач, көтүне хуҗасына тапшырсын!» – дип әйтә.

Давыт галәйһис-сәләәм бу тәкъдимне бик ошата һәм шундый хөкем чыгара. Аяти кәримәдә болай диелә:

وَدَاوُودَ وَسُلَيْمَانَ إِذْ يَحْكُمَانِ فِي الْحَرْثِ إِذْ نَفَشَتْ فِيهِ غَنَمُ الْقَوْمِ وَكُنَّا لِحُكْمِهِمْ شَاهِدِينَ

**«Давытны һәм Сөләйманны да искә ал! Менә алар чит кавемнең (төнлә көтүчесез калып) сарыклары таптаган игенлек хакында хөкем бирделәр. Без аларның хөкемнәренә шаһитлар идек»** («әл-Әнбия», 78).

فَفَهَّمْنَاهَا سُلَيْمَانَ وَكُلًّا آتَيْنَا حُكْمًا وَعِلْمًا وَسَخَّرْنَا مَعَ دَاوُودَ الْجِبَالَ يُسَبِّحْنَ وَالطَّيْرَ وَكُنَّا فَاعِلِينَ

**«Без аны (бу фәтваны) Сөләйманга аңлаткан идек. Һәрберенә дә хөкем һәм гыйлем (хөкемдарлык, пәйгамбәрлек) биргән идек...»** («әл-Әнбия», 79).

Хәзрәти Сөләйманның гаҗәеп зирәклеген һәм Хак Тәгаләгә ихлас бирелгәнлеген күреп, Давыт галәйһис-сәләәм унтугыз улы арасыннан аны үз урынына хәлифә итеп сайлый. Ләкин Исраил угыллары аның бу ниятенә: «Сөләйман бала гына әле, арабызда аннан өлкәнрәк һәм өстенрәкләр дә бар!» – дип каршы чыга. Шуннан соң Давыт галәйһис-сәләәм, илаһи әмергә ярашлы рәвештә, галимнәр күз алдында бер имтихан уздыра. Ул Сөләйманнан: «Дөреслеге башка әгъзаларның дөреслегенә, бозыклыгы да башкаларның бозыклыгына сәбәп булган әгъза ни ул?» – дип сорый.

Сөләйман галәйһис-сәләәм: «Йөрәк!» – дип җавап бирә. Бу җавапны бик ошаталар.

Аннары Давыт галәйһис-сәләәм һәркемнең таягына аның кемнеке икәнен язып, бер бүлмәгә бикли. Шулвакытта Сөләйман галәйһис-сәләәм таягының гына яшелләнеп, яфрак ярганын күрәләр. Аллаһның мондый рәхмәте каршында Давыт галәйһис-сәләәм хәмед-сәнәләр әйтә. Исраил угыллары исә Хәзрәти Сөләйманны үзләренә хәлифә итеп, бик сөенеп кабул итә.

Аллаһның рәхмәте һәм ярдәме белән хәлифәлек мәсьәләсен шул рәвешле хәл иткәч, Давыт галәйһис-сәләәм улы Сөләйман галәйһис-сәләәмгә мондый нәсыйхәтләр бирә:

«И, улым! Шаярту-көлүдән тыел, чөнки моның файдасы аз булып, үкенергә туры килер. Кызып китүдән дә саклан, чөнки ярсыган зат түбәнлеккә төшәр, дәрәҗәсен югалтыр. Тәкъвалыкка омтыл, чөнки тәкъвалык һәр эштә җиңеп чыга.

Кешеләрдән һичнәрсә көтмә. Менә шул чын байлыкның үзе булыр.

Аллаһ Җәллә Җәләлүһүнең сиңа бирмичә, башкаларга биргән нигъмәтләренә кызыгу синең өчен фәкыйрьлек дигән сүз.

Гафу үтенергә туры киләчәк эш-гамәлләрдән һәм сүзләрдән тыел!

Нәфесеңне һәм телеңне дөреслеккә, тугрылыкка күнектер!

Бүгенгене кичәгедән хәерлерәк итәргә тырыш!

Намазыңны иң соңгы намазын укучы зат кебек укы!

Түбәнлеккә төшкән, гөнаһка чумган бәндәләр белән аралашма!

Ачуың килгән вакытта, бу урыннан читкә кит!

Аллаһ Җәллә Җәләлүһүнең рәхмәтеннән өмет өзмә! Чөнки Аның рәхмәте һәрнәрсәне колачлый» (Сәләби, «Араис», 323 б.).

Давыт галәйһис-сәләәмнең вафатыннан соң Сөләйман галәйһис-сәләәм хөкемдарга әйләнә.

وَوَهَبْنَا لِدَاوُودَ سُلَيْمَانَ نِعْمَ الْعَبْدُ إِنَّهُ أَوَّابٌ

**«Давытка да Сөләйманны Без бирдек. Нинди күркәм бер кол иде (Сөләйман)! Чөнки, һичшиксез, ул күп тәүбә кылучы иде»** («Сад», 30).

Сөләйман галәйһис-сәләәмгә бик күп нигъмәтләр һәм хакимият бирелә:

وَلَقَدْ آتَيْنَا دَاوُودَ وَسُلَيْمَانَ عِلْمًا وَقَالَا الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي فَضَّلَنَا عَلَىٰ كَثِيرٍ مِنْ عِبَادِهِ الْمُؤْمِنِينَ

**«Без Давытка һәм Сөләйманга гыйлем бирдек тә, алар: “Барча мактаулар – Аллаһныкы гына, Ул иман китергән колларының күбесеннән безне өстен кылды”, – диделәр»** («ән-Нәмел», 15).

Хәзрәти Сөләйман кошлар телен, аларның тәсбих кылуын аңлый.

وَوَرِثَ سُلَيْمَانُ دَاوُودَ وَقَالَ يَا أَيُّهَا النَّاسُ عُلِّمْنَا مَنْطِقَ الطَّيْرِ
وَأُوتِينَا مِنْ كُلِّ شَيْءٍ إِنَّ هَذَا لَهُوَ الْفَضْلُ الْمُبِينُ

**«Сөләйман Давытка мирасчы булды һәм: “И, кешеләр! Безгә кошларның теле өйрәтелде һәм һәрнәрсәдән безгә бирелде. Һичшиксез, бу – ачык бер игелек”, – дигән иде»** («ән-Нәмел», 16).

Кешеләр, җеннәр, хайваннар һәм җил аңа буйсындырыла, аның хакимлегенә бирелә.

وَلِسُلَيْمَانَ الرِّيحَ عَاصِفَةً تَجْرِي بِأَمْرِهِ إِلَى الْأَرْضِ الَّتِي بَارَكْنَا فِيهَا وَكُنَّا بِكُلِّ شَيْءٍ عَالِمِينَ

**«Сөләйманга исә көчле искән җилне (бирдек). Ул Без бәрәкәтләндергән туфракка аның әмере белән алып бара. Без һәрнәрсәне беләбез»** («әл-Әнбия», 81).

وَلِسُلَيْمَانَ الرِّيحَ غُدُوُّهَا شَهْرٌ وَرَوَاحُهَا شَهْرٌ وَأَسَلْنَا لَهُ عَيْنَ الْقِطْرِ وَمِنَ الْجِنِّ مَنْ
يَعْمَلُ بَيْنَ يَدَيْهِ بِإِذْنِ رَبِّهِ وَمَنْ يَزِغْ مِنْهُمْ عَنْ أَمْرِنَا نُذِقْهُ مِنْ عَذَابِ السَّعِيرِ

**«Сөләйманга – җилне (бирдек), иртәнге юлы бер ай, кичке юлы да бер ай иде. Без аның өчен бакыр чишмәсе агыздык. Җеннәрдән шундыйлары бар иде, Раббысының рөхсәте белән аның алдында эшлиләр иде. Алардан кайсысы Безнең әмеребездән тайпылса, аңа Ут газабыннан татыттыра идек»** («Сәбә», 12).

يَعْمَلُونَ لَهُ مَا يَشَاءُ مِنْ مَحَارِيبَ وَتَمَاثِيلَ وَجِفَانٍ كَالْجَوَابِ وَقُدُورٍ
رَاسِيَاتٍ اعْمَلُوا آلَ دَاوُودَ شُكْرًا وَقَلِيلٌ مِنْ عِبَادِيَ الشَّكُورُ

**«Алар аңа (Сөләйманга) теләгән нәрсәләрен ясыйлар, нык сарайлар, һәйкәлләр, сулыклар кебек савытлар һәм какшамас казаннар ясыйлар иде. И, Давыт токымы! Шөкер өчен гамәлдә булыгыз, ләкин колларыбыздан шөкер иткәннәр бик аз»** («Сәбә», 13).

Әлеге аяти кәримәдә очраган «тәмасил» сүзе тере яисә җансыз нәрсәләрнең бакыр, балчык яки пыяладан ясалган һәйкәлләре, рәсем-сурәтләре рәвешендә аңлатыла. Сүзнең кулланышына, дәлилләмәсенә күрә, аять җанлы һәм җансыз нәрсәләрнең рәсемнәрен белдерә. **«Тәмасил»** сүзе аятьтә гомуми мәгънә белдергәнлектән, Хәзрәти Сөләйманның шәригатендә тере һәм җансыз бөтен мәхлукларның, җисемнәрнең сурәт-рәсемнәрен яки сыннарын ясау рөхсәт ителгән дип аңларга мөмкин. Бу мәсьәләдә мөфәссирләр арасында фикерләр төрле. Аларның карашларын икегә туплап карый алабыз:

1. Мөфәссирләрнең бер өлеше Хәзрәти Сөләйманның шәригатендә җан ияләренең сурәтен һәм сыннарын ясау рөхсәт ителмәгәнлеген, чөнки Хәзрәти Сөләйманның Хәзрәти Муса шәригатенә буйсынуын, ә анда җан иясенең рәсемен ясау ачыктан-ачык тыелганлыгын белдерә. Бу фикергә күрә, «тәмасил» сүзе җансыз предметларның рәсемнәренә генә кагыла. Шул рәвешле исламдагы җанлы нәрсәләрне ясауга бәйле тыюга туры килә. Әгәр Сөләйман галәйһис-сәләамнең шәригатендә рәсемнәргә, һәйкәлләргә рөхсәт бирелгән икән, моның ул заманнарда әле потларга табыну куркынычы булмаганлыктан килеп чыга, дип фикерләргә мөмкин.

2. Кайбер мөфәссирләр исә Хәзрәти Сөләйман шәригатендә җанлы һәм җансыз нәрсәләрнең сынын яки рәсемен ясау рөхсәт ителгән, дигән фикерне яклый. Ул очракта сорау туа: «Коръәни-Кәримдә бу хакта әйтелгәч, җанлы

һәм җансыз нәрсәләрнең сынын яки рәсемен ясау исламда да рөхсәт ителә, дигән хөкем чыгарып буламы?» Мондый сорауга ислам факиһләре һәм мөфәссирләр: «Исламда пейзаж, тау, урман һәм агач кебек җансыз нәрсәләрнең һәм үсемлекләрнең рәсемен генә ясарга ярый», – дип хөкем чыгарган, чөнки Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм шактый хәдис-шәрифендә җан ияләренең рәсемен ясауны тыйган. Рәсем белән бәйле хәдис-шәрифләр бу мәсьәләгә ачыклык кертә.

Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмәнең риваятенә күрә, Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез: *«Кем дөньяда берәр җан иясенең рәсемен ясаса, кыямәт көнендә шул ясаган рәсеменә җан кертергә кушылыр. Ул зат исә (рәсемгә) һич җан бирә алмас»*, – дип әйткән (Бохари, «Либас», 97; «Тәгъбир», 45; Мөслим, «Либас», 100).

Шулай ук, Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмә сөйләгәнчә, Мәккәне яулаган көнне, Бәйтуллаһта сурәтләр күргәч, Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм аның эченә кермәгән, бу рәсемнәрне юк итәргә кушкан. Бина эчендә Ул Хәзрәти Ибраһим һәм Хәзрәти Исмәгыйль галәйһимәс-сәләмнәрнең кулларына фал уклары тоткан рәвештәге сурәтләрен күргән. Пәйгамбәребез: *«Аллаһ (бу рәсемнәрне ясаучыларның) җаннарын алсын! Валлаһи, алар (Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимәс-сәләм) һичкайчан язмышларын ук белән эзләмәделәр»* (Бохари, «Әнбия», 8; «Хаҗҗ», 54; «Мәгази», 48).

Нәтиҗә буларак, Хәзрәти Сөләйман шәригатендә җан ияләренең сурәтләрен һәм сыннарын ясауга рөхсәт булган дип кабул ителгән очракта да, бу гамәл исламда катгый тыела.

Ибне Мәсгуд радыйаллаһу ганһе хәбәр иткәнчә, Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм җан иясенең рәсемен ясаучыларга кыямәт көнне газапның иң көчлесе биреләчәген белдергән (Бохари, «Либас», 89; Мөслим, «Либас», 96). Чөнки рәсем һәм һәйкәлгә чиктән тыш игътибар-хөрмәт күрсәтү нәтиҗәдә кешеләрне потпәрәстлеккә алып килә.

Хәзрәти Гайшә радыйаллаһу ганһә сөйләгәннәрдән:

Җәбраил галәйһис-сәләәм Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына билгеле бер сәгатьтә килергә вәгъдә итә. Әйтелгән вакыт җитә, ләкин Җәбраил галәйһис-сәләәм килми. Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кулындагы таякны җиргә ташлый да: *«Аллаһ та, Аның рәсүлләре дә вәгъдәсеннән тайпылмас!»* – дип әйтә. Аннары тирә-ягына карана башлый һәм сәкесенең астында бер көчекне күреп ала! Шуннан соң Ул: *«Әй, Гайшә! Бу көчек кайчан керде монда?»* – дип аваз салды. Мин: «Аллаһ белән ант итәм, белмим», – дидем. Аның әмере белән көчекне алып чыгып киттеләр. Шундук Җәбраил галәйһис-сәләәм дә килә.

Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Миңа сүз бирдең, мин көттем, тик син килмәдең»*, – ди.

Җәбраил галәйһис-сәләәм: «Миңа өегездәге эт комачаулады. Без, фәрештәләр, эчендә эт һәм сурәт булган йортка кермибез», – дип җавап бирә (Мөслим, «Либас», 81, 82. Шулай ук карагыз: Бохари, «Бәдгуль-халк», 7, «Либас», 94; Ибне Мәҗә, «Либас», 44).

Бу хәдис-шәрифтә «эт» белән бергә искә алынган «сурәт» бары рәсемне генә күздә тотмый. Аңа җан ияләренең сыннары яки барельеф кебек кабартып ясалган сурәтләре дә керә. Рәсем исә бер шәүләнең проекциясе кебек, аның күләме юк. Шул ук вакытта «сурәт» сүзе һәртөрле җан иясенең рәсемен колачлаган төшенчә буларак каралган очракта да, бу хактагы тыюның, потларга табыну чорының якынлыгы сәбәпле, барлыкка килүен дә күзалларга мөмкин.

Икенче яктан карганда, хәзерге заманда рәсем һәм фотографияләрнең көндәлек тормышта кулланылыш мохите киңәюе һәм кайбер очракларда зарури ихтыяҗга әверелүе билгеле. Динамик структурага ия ислам дине заман дәвамында зарурият дәрәҗәсенә күтәрелгән мондый төр ихтыяҗлар өчен билгеле бер канун-кагыйдәләр чиге билгеләп, сурәт һәм фотографияләр куллануга рөхсәт бирә.

Сүз уңаеннан, шуны да искә алып үтик: югарыдагы хәдис-шәрифтә белдерелгәнчә, эчендә эт булган өйгә фәрештә кермәве дә мөһим хикмәткә ишарәли. Бөек ислам динебез өй эчендә эт асрауны тыя, чөнки этнең сулышы һәм селәгәе нәҗес санала. Этләрнең селәгәеннән, йоннарыннан һәм хәтта сулышларыннан төрле йогышлы авырулар килеп чыкканлыгы хәзерге заманда шик уятмый торган фәнни факт булып тора. Өстәвенә болар – фәннең бүгенге ирешелгән дәрәҗәсендә раслана ала торган хакыйкатьләр. Исламның бу мәсьәләдәге чик-үлчәмнәренең әле ачыкланмаган күпме хикмәте барлыгын һичкем белмәс.

Хәдис-шәрифтә әйтелгәнчә, өйгә очраклы рәвештә кергән бер көчек аркасында Җәбраил галәйһис-сәләәм Пәйгамбәр Әфәндебез галәйһис-саләтү вәс-сәләәм янына килә алмаган. Бернинди сәбәпсез, үз ихтыярлары белән эт асраган өйләрнең хәлен уйлап карагыз! Рәсүл Әкрәм Әфәндебезнең Хәзрәти Гайшәгә*: «Бу көчек кайчан керде монда?»* – дип соравы һәм аның: «Валлаһи, белмим», – дип ант итеп җавап бирүе дә бер мөселманның өендә эт тотуы турында сүз дә булырга мөмкин түгеллеген күрсәтә. Бу вакыйга да бер сәбәпсез түгел, ә мөэминнәр өчен бер хөкемнең ачыклану хикмәтенә нигезләнеп чынга аша.

Песи – йортка ияләшкән хайван, аның өйдә яшәвенә карата нindидер тыю юк, әмма өйдә эт асрау рөхсәт ителми. Ә аучылык, көтүчелек, йорт-җир, бакчаларны саклау өчен эт асрау тыелмый, ләкин анысы да йортка кертмичә генә. Чөнки бу очракта эт билгеле бер ихтыяҗны канәгатьләндерә.

Чыннан да, Җәнабел-Хак этне кешегә буйсындырган һәм аны бик күп хайваннардан аермалы буларак, хуҗага тугрылык сыйфатына ия җан иясе

иткән. Өстәвенә, аңа бик күп заманча приборлар да ия булмаган искиткеч сәләтләр бирелгән. Әйтик, бүген наркотик эзләү яки хәрабәләр, җимерекләр астында калган кешеләрне табу өчен кулланылган этләр, йорт-җир, бакчаларны саклау хезмәтенә өстәмә рәвештә, кешеләрнең саулыгын-иминлеген саклау өлкәсендә дә гаҗәп әһәмиятле хезмәтләр башкара.

Бүген, аеруча Көнбатыш илләрендә, гаилә институты бик еш таркала һәм кешеләр ялгыз гомер кичерә башлый, шунлыктан алар, караклардан һәм башка күңелсез хәлләрдән саклану өчен, өйдә эт асрый. Өстәвенә, күп кенә Көнбатыш илләрендә өйдә асралган этләр мәҗбүри рәвештә иминиятләштерергә тиеш. Этләрен ашату-эчертү чыгымнарына иминиятләштерү чыгымнары да өстәлә, ләкин кешеләр аларны түләүдә юмарт кыланып, һич авырсыну сиздерми, ә менә җәмгыятьтәге фәкыйрьләргә карата андый юмартлык күрсәтелми. Аларның бик күп мәшәкатьләрне һәм чыгымнарны күздә тотып, өйдә эт асравы вакыт узу белән, этнең дә, аның хуҗасының да холкын боза. Чөнки эткә артык игътибар күрсәтү аны гаиләнең бер әгъзасы дип кабул итү дәрәҗәсенә җитә. Мондый чиктән ашулар хәтта вакыт-вакыт үз balaңның да арткырак планга калуына килеп җитәргә мөмкин. Моның иң куркыныч нәтиҗәсе исә эгоистлыкның үсеп-ныгып, балага күрсәтелергә тиешле мәхәббәтнең эткә юнәлтелүе аркасында бала тәрбияләү, бала үстерү теләгенең сүрелүеннән гыйбарәт. Хәзерге заманда күп кенә Көнбатыш дәүләтләрендә халык саны, артасы урында, кими бара. Өстәвенә, өйдә эт асралу – эткә карата да ниндидер игелек, аны яклау ысулы түгел, киресенчә, бер яктан караганда, ул үз яратылышына ят шартларда яшәргә мәҗбүр ителә.

Заманнан алда барган исламның этләрне бары тик йорт тышында һәм билгеле бер ихтыяҗ очрагында гына асрарга рөхсәт итүенә каршы, Көнбатыш халкының мондый мөнәсәбәте никадәр куркыныч адашу һәм гаилә институтын җимерү дигән сүз. Ни кызганыч, соңгы вакытларда безнең җәмгыятебездә дә күзәтелә башлаган өйдә эт асрау гадәте Көнбатышка сукырларча иярүнең тискәре чагылышыннан бары берсе генә әле.

Исламның өйдә эт асрау мәсьәләсендәге тыюы бу хайванга карата тискәре мөнәсәбәттә торуны таләп итми, ягъни этләрне асрамаска, ашатмаска яки аларга карата начар мөгамәләдә булырга дигән сүз була да алмый. Киресенчә, ислам мәрхәмәт хисен бөтен мәхлукларга җитәрлек рәвештә сеңдергәнгә күрә, башка мәхлуклар белән беррәттән, этләргә дә мәрхәмәтле мөнәсәбәт булдырырга куша.[147] Әйтик, бер хәдис-шәрифтә гөнаһлы хатынга, сусызлыктан үләр дәрәҗәгә җиткән бер эткә су биргән өчен, җәннәт әһеле булачагы турында шатлыклы хәбәр җиткерелә.

Үткәнебездә мәхлукларга карата мәрхәмәт тойгысының социальләшеп, төрле вакфлар корылуы, бу вакфларның шәфкать кулы яклауга мохтаҗ хайваннарга да ирешкәнлеге мәгълүм һәм дан казана.

147. Карагыз: Мөслим, «Сәлам», 151–155.

Димәк, монда иң мөһиме – эт асрау мәсьәләсендә дә ислам билгеләгән кагыйдәләрнең чикләрен саклау, аларны үтәү кирәклеге.

**Сөләйман галәйһис-сәләәмнең ат яратуы**

Аяти кәримәләрдә болай дип хәбәр ителә:

إِذْ عُرِضَ عَلَيْهِ بِالْعَشِيِّ الصَّافِنَاتُ الْجِيَادُ فَقَالَ إِنِّي أَحْبَبْتُ حُبَّ الْخَيْرِ عَنْ ذِكْرِ رَبِّي حَتَّىٰ تَوَارَتْ بِالْحِجَابِرُدُّوهَا عَلَيَّ فَطَفِقَ مَسْحًا بِالسُّوقِ وَالْأَعْنَاقِ

**«Менә өйләдән соң аңа, өч аягында торып, бер аягының тоягы чак җиргә тигән һәм тиз чаба торган атлар күрсәтелде. Ул әйтте: “Һичшиксез, мин мал яратуны Раббымны зикер итүдән өстенрәк куйган булдым, нәтиҗәдә, ул (атлар) пәрдә белән капланды. Аларны миңа кире кайтарыгыз”, – диде. Шуннан ул балтырларыннан һәм муеннарыннан чала башлады (сыйпады)»** («Сад», 31–33).

Бер төркем мөфәссирләр фикеренчә, Хәзрәти Сөләйман галәйһис-сәләәм: «Мин атларны Раббымны зикер итү сәбәпле яраттым!» – дигән. Ягъни намазына яки зикеренә зыян китермәгән. Ахырда ул атлар пәрдә артына яшеренә. Алар абзарларга бикләнә яки йөгереп китеп күздән югала, менә шулвакытта Сөләйман галәйһис-сәләәм намазын тәмамлый. Шуннан соң: «Аларны миңа кире кайтарыгыз!» – ди. Аннары аякларын, муеннарын сыйпый башлый, төкләрен иркәли.

Фәхреддин Разый әйтүенчә, исламдагы кебек, Хәзрәти Сөләйман шәригатендә дә яу-сугышлар өчен ат үрчетү мөстәхәб санала. Беркөнне Хәзрәти Сөләйман атларны тикшерергә чыга. Өч аягына басып, бер аягының тоягын гына җиргә тидерер-тидермәс торган мәһабәт атлар теземен күргәч: «Мин бары Раббымның исемен искә алыр өчен генә, ягъни Аның ризалыгына ирешү һәм Аның исемен тарату өчен генә дөнья малын сөйдем; нәфесем өчен байлыкка омтылмадым!» – дигән. Аннары ат караучыларга аларны чаптырырга куша, җилдәй җитез чапкан атлар күздән югалганчы, бу хайваннарны күзәтеп торганнан соң, ат караучыларга: «Аларны миңа алып килегез!» – дип боера. Үзе янына алып килгән атларны сыйпый-сыйпый сөя. Шул рәвешле Раббының кодрәте һәм сәнгатенең күркәм чагылышына шаһит була.

Аяти кәримәдән аңлашыла ки, тик торгандагы һәм хәрәкәт вакытындагы матурлыклары аша атлар да илаһи кодрәтнең бер чагылышын күрсәтәләр. Кешелек тарихы дәвамында ат батыр сугышчыларның каһарманлыкларының, җиңүләренең алхәбәрчеләре, дан казануда төп ярдәмчеләре була.

Ат Аллаһ Тәгалә Коръәни-Кәримдә үзе белән ант иткән искиткеч мәхлуклардан:

وَالْعَادِيَاتِ ضَبْحًا فَالْمُورِيَاتِ قَدْحًا فَالْمُغِيرَاتِ صُبْحًا فَأَثَرْنَ بِهِ نَقْعًا فَوَسَطْنَ بِهِ جَمْعًا

**«(Аллаһ юлында) тыннары бетеп чабып барган атлар белән ант итәмен. Очкыннар чыгарганнар белән. Таң вакытында яу ясаучылар белән. Алар анда тузан күтәрделәр. Шуннан соң алар анда төркем уртасына бәреп керделәр»** («әл-Гадият», 1–5).

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм атлар турында болай дигән:

*«Кыямәт көненәчә атларның маңгайларына хәерлесе, ягъни әҗер һәм ганимәт төенләп куелган».* (Бохари, «Җиһад», 43; Мөслим, «Имарә», 96–99).

*«Кем Аллаһка чын-чынлап инанып һәм вәгъдәсенә ихлас тугры калып, Аның юлында җиһад кылу өчен ат асраса, ул атның ашаган-эчкән нәрсәләре, тиресе, бәвеле кыямәт көнне бу затның саваплары исемлегендә булачак»* (Бохари, «Җиһад», 45; Нәсаи, «Хайл», 11).

Атлар – кешеләргә рухи яктан иң якын мәхлуклар. Сугышка керергә җыенган хәрби атны үз холык-табигатенә ярашлы итеп сайлый, чөнки дошман каршында атлар үзенә атланган сугышчы белән бер үк хис-тойгыларны кичерер. Шул ук вакытта ат илаһи кодрәт гәүдәләнеше дә булып тора. Аның килеш-кыяфәте дә күзләрне хушландырырлык матурлык һәм нәфислеккә ия.

### Сөләйман галәйһис-сәләәмнең сынауга тотылуы

Беркөнне Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Сөләйманны сынап карый һәм мизгел эчендә аның бөтен кодрәтен тартып ала. Аяти кәримәдә бу вакыйга турында болай диелә:

وَلَقَدْ فَتَنَّا سُلَيْمَانَ وَأَلْقَيْنَا عَلَىٰ كُرْسِيِّهِ جَسَدًا ثُمَّ أَنَابَ

**«Без Сөләйманны сынаган идек һәм тәхетенә бер гәүдә ыргыткан идек. Шуннан соң ул (тәүбә белән әүвәлге хәленә) кайтты»** («Сад», 34).

Сөләйман галәйһис-сәләәм бер мизгелдә бөтен көч-куәтен югалта, һичнәрсәсе калмый.

Бу аятьтәге «фетнә» сүзе, ягъни имтихан турында төрле риваятьләр бар:

1. «Әл-Әкъса» мәчетен төзеткән вакытта, Хәзрәти Сөләйман чакырып китергән сәнгатькярләр арасына сәнгать хәйләләрен белгән бер төркем шайтаннар да эләгә, алар корган фетнә аркасында пәйгамбәр күпмедер вакыт хакимлеген югалта, ягъни тәхеттән читләштерелә; бу эш ике рәвештә чынга ашырылган булырга мөмкин: йә ул үзе көч-куәтсез, хөкем чыгарырга сәләтсез гәүдә хәлендә тәхеттә утырып кала яки, тәхете яулап алынып, пәйгамбәр урынына тәхеттә кырык көнгә һәйкәл шикелле бер нәрсә бастырып куела.

2. Бер риваятьтә Сөләйман галәйһис-сәләәм хатыннарының һәркайсына ир бала табарга куша һәм аларның Аллаһ юлында кяферләр белән җиһадка күтәрелүен тели. Ләкин бу вакытта «иншә Аллаһ», дип Аллаһның исемен телгә алырга оныта. Шуннан соң бер хатыны гына ир бала таба, анысы да гарип булып дөньяга килә (Бохари, «Әнбия», 40, «Әйман», 3; Мөслим, «Әйман», 23/1654).

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез дә, Үзеннән җан, әсхабе кәһф һәм Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәм турында сорагач: *«Иртәгә килегез, бу хакта мәгълүмат бирермен!»* – дип озатып җибәрә. Ләкин «иншә Аллаһ», дип әйтергә оныта. Шул сәбәпле Пәйгамбәребезгә дә берникадәр вакыт вәхи килми тора. Аллаһ Тәгалә болай дип кисәтә:

وَلَا تَقُولَنَّ لِشَيْءٍ إِنِّي فَاعِلٌ ذَلِكَ غَدًا إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللَّهُ وَاذْكُرْ رَبَّكَ
إِذَا نَسِيتَ وَقُلْ عَسَىٰ أَنْ يَهْدِيَنِ رَبِّي لِأَقْرَبَ مِنْ هَذَا رَشَدًا

**«Берни турында да: “Мин моны иртәгә эшләячәкмен”, – дип әйтмә, “мәгәр Аллаһ теләсә” (“иншә Аллаһ”, дип әйтмичә). Әмма оныткан чагыңда Раббыңны исеңә төшер һәм: “Бәлки, Раббым мине моннан да якынрак булган бер юлга ирештерер”, – дип әйт!»** («әл-Кәһф», 23–24).

3. Башка бер карашка күрә, Сөләйман галәйһис-сәләәм бик көчле авыру белән сынала. Шул сәбәпле тәхетендә җансыз бер гәүдә кебек булып кала.

4. Тагын бер риваятькә күрә исә, Аллаһ Тәгалә Сөләйман галәйһис-сәләәмнең эченә бер курку сала. Бер-бер бәла-каза киләчәк, дип борчылып, пәйгамбәр җансыз бер гәүдәгә әйләнә.

Соңыннан, Аллаһның рәхмәте белән, Сөләйман галәйһис-сәләәмгә кабат әүвәлге халәте кайтарыла.

Сөләйман галәйһис-сәләәм болай дип тәүбә кыла:

قَالَ رَبِّ اغْفِرْ لِي وَهَبْ لِي مُلْكًا لَا يَنْبَغِي لِأَحَدٍ مِنْ بَعْدِي إِنَّكَ أَنْتَ الْوَهَّابُ

**«Әйтте: “И, Раббым! Мине ярлыка һәм миңа шундый хакимлек бир ки, миннән соң беркем дә андыйга лаек булмасын. Һичшиксез, Син – Бүләкләүчесең”»** («Сад», 35).

Сөләйман галәйһис-сәләәмнең үзенә һичкемнең кодрәте җитмәслек көч-сәләтләрне мактану, шапырыну өчен сорамый. Бу көч-сәләтләр ул замандагы залим падишаһларны хурлыкка калдыру өчен таләп ителә, чөнки Сөләйман чорында явызлык кылучы тәкәббер падишаһлар була.

Фәхреддин Разый Сөләйман галәйһис-сәләәмнең догасында менә мондый мәгънә дә күрә:

«Раббым! Миңа шундый данлы бер мөлкәт һәм хакимлек бир, мин аңа ирешеп үлгәннән соң, “Дөнья малының файдасы булса, Сөләйманга тигән булыр иде!” – дип әйтсеннәр һәм һичкемнең дөньялыкта байлык-хакимлеккә хирыслыгы һәм омтылышы калмасын!»

Бу аңлатмадан күренгәнчә, Сөләйман галәйһис-сәләәмнең төп максаты дөнья байлыгына түгел, ә ахирәт зиннәтенә ирешергә теләүдән гыйбарәт. Аяти кәримәдә болай диелә:

مَنْ كَانَ يُرِيدُ حَرْثَ الْآخِرَةِ نَزِدْ لَهُ فِي حَرْثِهِ وَمَنْ كَانَ يُرِيدُ
حَرْثَ الدُّنْيَا نُؤْتِهِ مِنْهَا وَمَا لَهُ فِي الْآخِرَةِ مِنْ نَصِيبٍ

**«Кем дә кем Ахирәт игенен теләсә, аның өчен игенен арттырырбыз, кем дә кем дөнья игенен теләсә, аңа да аннан бирербез. Әмма Ахирәттә аның өчен бернинди дә насыйп юк»** («әш-Шура», 20).

Түбәндәге аяти кәримәдә хәбәр ителгәнчә, Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Сөләйманның догасын кабул итә:

فَسَخَّرْنَا لَهُ الرِّيحَ تَجْرِي بِأَمْرِهِ رُخَاءً حَيْثُ أَصَابَ وَالشَّيَاطِينَ
كُلَّ بَنَّاءٍ وَغَوَّاصٍ وَآخَرِينَ مُقَرَّنِينَ فِي الْأَصْفَادِ

**«Без аңа җилне буйсындырдык, ул аның әмере белән йомшак бер хәлдә ул теләгән җиргә агып китә иде. Төрле бина салган һәм гауүас[148] шайтаннарны да. (Яманлык кылмасыннар өчен) чылбырлар белән бер-берсенә бәйләнгән бүтәннәрне дә (ягъни җеннәрне яки кяфер кабиләләрне, колларны һәм әсирләрне дә аңа буйсындырдык)»** («Сад», 36–38).

Әлеге аятьләрдән аңлашылганча, Аллаһ Тәгалә төзелеш алып бару һәм диңгезгә чумып энҗе эзләү өчен, шайтаннарны (җеннәрне) Хәзрәти Сөләйман галәйһис-сәләәмгә буйсындыра. Бу шайтаннарның бер өлеше Хәзрәти Сөләйман кушканча зур-зур биналар, мәчетләр, сарайлар төзи, аларга сурәтләр төшерә, бассейннар, ныклы зур казаннар ясый. Андый эшләргә кешеләрнең көче җитмәгән булыр иде. Ул шайтаннарның бер өер өлеше исә диңгезләрдән төрле-төрле нигъмәтләр, җәүһәрләр, диңгездә генә табыла ала торган матур нәрсәләр чыгара.

Аяти кәримәдәге «чылбырлар белән бер-берсенә бәйләнгән бүтәннәрне» гыйбарәсе исә ике төрле аңлатыла:

1. Кайбер мөфәссирләр бу сүзләрне Сөләйман галәйһис-сәләәм кул астында булган коллар һәм әсирләр дип тәфсир кыла. Андый тәфсиргә күрә,

148. Гауүас – су төбенә чумучы, водолаз, энҗе эзләүче.

эшләсеннәр һәм качмасыннар өчен, Хәзрәти Сөләйман колларны һәм әсирләрне шулай бәйләтеп куйган.

2. Бер төркем мөфәссирләр исә бу сүзләр кайбер шайтаннарның (жен-нәрнең), Хәзрәти Сөләйман кушканнарга каршы килгәнгә, чылбырга бәйләп эшләтелүе һәм шул рәвешле җәзалануын белдерә дип саный. Күп очракта менә шушы икенче карашка өстенлек бирелә. Ибне Кәсир дә икенче карашны кабул итә һәм, чылбыр белән бәйләп куелганнар, дигәндә, гыйсьянчы, эштән баш тартучы, киреләнүче яки эшен тиешенчә башкармаучы шайтаннар төркеме турында сүз бара, дип аңлата.

Хәзрәти Сөләйманга мондый кодрәт һәм хакимият биргән Аллаһ Тәгалә Аңа мал-мөлкәтне иркен тоту, сарыф кылу мөмкинлеген дә насыйп итә.

Җәнабел-Хак болай ди:

هَٰذَا عَطَاؤُنَا فَامْنُنْ أَوْ أَمْسِكْ بِغَيْرِ حِسَابٍ وَإِنَّ لَهُ عِنْدَنَا لَزُلْفَىٰ وَحُسْنَ مَآبٍ

**«“Бу – Безнең бүләгебез. Син (теләсәң) хисапсыз игелек кыл яки үзеңдә тотып тор”, – дидек. Һичшиксез, ул Безгә якын (югары дәрәҗәле) һәм аның өчен күркәм кайту урыны бар»** («Сад», 39–40).

Әбү Һурайра радыйаллаһу ганһедән Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм түбәндәге хәдисе риваять кылына:

*«Женнәрдән бер гыйфрит кичә кич, намазымны бозар өчен, өстемә сикерде. Аллаһ миңа мөмкинлек бирде дә мин бу җенне бик шәпләп эләктереп алдым. Хәтта таң каткач һәркайсыгыз күрсен, дип, аны мәчетнең бер баганасына бәйләп куярга теләдем. Ләкин туганым Сөләйман галәйһис-сәләамнең: “Раббым! Мине ярлыка һәм миңа шундый хакимлек бир ки, миннән соң беркем дә андыйга лаек булмасын”, – дигән сүзләре искә төште»* («Сад», 35). Аллаһ ул җенне хурлыкка калдырып, көчсезләндереп тартып алды» (Бохари, «Саләт» 75; «Әнбия», 40; Мөслим, «Мәсаҗид», 39/541).

Үзенә шулкадәр зур байлык һәм чиксез хакимлек бирелүенә карамастан, Сөләйман галәйһис-сәләам һәрдаим ихлас бирелгәнлек, хошуглык һәм тәкъвалык белән гыйбадәт кылып яшәп, йөрәген дөньялык мәнфәгатьләреннән саклап кала ала. Аның мондый фазыйләте турында: «Сөләйман галәйһис-сәләам үзенә бирелгән мал-мөлкәткә карамастан, Аллаһка каршындагы тәкъвалыгы, хошуглыгы сәбәпле, үлгәнче башын күккә күтәреп карамый», – дип әйтелгән (Ибне Әби Шәйбә, «Мусаннәф», VIII том, 118 б.).

### Бәйтүл-Макдисне төзү

Давыт галәйһис-сәләам Аллаһ Җәллә Җәләлүһү әмере белән Бәйтүл-Макдисне төзи башлый, тик бу эшкә гомере җитми кала. Шуннан соң Сөләйман

галәйһис-сәләәм җеннәрне җыя һәм Бәйтүл-Макдиснең төзелешен шулар белән дәвам итә. Аның тирәсенә унике мәхәлләле бер шәһәр дә салдыра (б.э. кадәр 967 яки 953 еллар).

Баштагы чорда «Бәйтүл-Макдис» дип аталган бу гыйбадәтханә соңыннан «әл-Әкъса» мәчетенә (Мәсҗидүл-Әкъса) әйләнә. Фазыйләте ягыннан өч олуг мәчетнең берсе булып тора. Әлеге өч мәчетнең беренчесе – «әл-Хәрәм» мәчете (Мәсҗидүл-Харам – Кәгъбә), икенчесе – «Пәйгамбәр мәчете» (Мәсҗиден-Нәбәви), өченчесе исә – «әл-Әкъса» мәчете. Эченә мөкатдәс әманәтләр һәм Тәүрат ләүхәләре салынган табут та шушы мәчеттә саклана.

Сөләйман галәйһис-сәләәмнең вафатыннан соң, төрле чорларда Бәйтүл-Макдис берничә тапкыр җимерелә. Әйтик, б.э. кадәр 586 еллар тирәсендә Бухтүннаср (Навуходоносор) Иерусалимгә бәреп керә һәм шәһәрне яндыра, «әл-Әкъса» мәчетенең байлык-җәүһәрләрен Вавилонга алып китә. Бәйтүл-Макдис озак елларга хәрабә хәлендә кала. Вавилонлыларны җиңеп, фарсылар яһүдиләрнең кабат әүвәлге җирләренә кайтуына һәм гыйбадәтханәне яңадан торгызуларына рөхсәт биргәч, б.э. кадәр 515 елда изге бина икенче тапкыр төзелә. Ләкин безнең эраның 70 елында римлылар гыйбадәтне җимереп, яндыра. Бәйтүл-Макдис торган урын шактый вакыт буш кала. Шулай да бу изге җирнең барыбер гыйбадәт урыны икәне чамалана һәм хәрабәләре саклана. Милади белән 637 елда Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһенең монда бер мәчет салдыруы риваять кылына. 691 елда әмәвиләр хәлифәсе Габделмәлик Пәйгамбәр Әфәндебез мигъраҗда аяк баскан урынга Кыя гөмбәзе мәчетен (Мәсҗиди Күббәтүс-Сәхра), ә аның янәшәсенә «әл-Әкъса» мәчетен салдыра. Төзелеш эшләре аның улы Вәлид I чорында тәмамлана. «Әл-Әкъса» мәчете бүгенге хәленә килеп җиткәнче, күп тапкыр төзекләндерелә һәм үзгәртеп корыла.

«Әл-Әкъса» мәчете динебездә дәрәҗәле урын били һәм бик фазыйләтле гыйбадәтханә санала, чөнки ул исламның тәүге кыйбласы булып тора. Һиҗрәтнең уналтынчы аена кадәр мөселманнар «әл-Әкъса» мәчетенә юнәлеп намаз укый. Моннан тыш, «әл-Әкъса» «исра» вакыйгасының тәмамлану, мигъраҗның башлану ноктасы да була.

Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдис-шәрифендә: *«(Зиярәт кылу максаты белән) өч мәчеткә генә сәяхәт итәргә мөмкин: “әл-Хәрәм” мәчете, минем шушы мәчетем һәм “әл-Әкъса”»*, дип әйтә (Бохари, «Фәдаилүс-Саләт», 6; Мөслим, «Хаҗҗ», 288/827).

Башка хәдис-шәрифтә болай диелә:

*«Бәйтүл-Макдисне төзегән вакытта, Хәзрәти Сөләйман Аллаһтан үзенә өч үзенчәлек, өч сыйфат бирүен сорый:*

*– Илаһи хөкемгә туры килә торган хөкем чыгару сәләте; бу сәләт аңа бирелә.*

*– Үзеннән соң һичкемгә бирелмәслек хакимлек; бу да бирелә.*

*– Мәчетнең төзелешен бетергәннән соң, бу мәчеткә намаз кылу өчен генә килүчеләрнең, аннан чыкканда, анадан туган көнге кебек бөтен гөнаһлары гафу ителгән хәлдә чыгуларын; бу догасы да кабул ителә»* (Нәсаи, «Мәсаҗид», 6; Ибне Мәҗә, «Икамәтүс-Саләт», 196/1408).

**Сөләйман галәйһис-сәләәм һәм кырмыскалар**

Җәнабел-Хак болай дип хәбәр итә:

وَحُشِرَ لِسُلَيْمَانَ جُنُودُهُ مِنَ الْجِنِّ وَالْإِنْسِ وَالطَّيْرِ فَهُمْ يُوزَعُونَ حَتَّىٰ إِذَا أَتَوْا عَلَىٰ وَادِ النَّمْلِ قَالَتْ نَمْلَةٌ يَا أَيُّهَا النَّمْلُ ادْخُلُوا مَسَاكِنَكُمْ لَا يَحْطِمَنَّكُمْ سُلَيْمَانُ وَجُنُودُهُ وَهُمْ لَا يَشْعُرُونَ

**«Җеннәрдән, кешеләрдән һәм кошлардан торган гаскәрләр Сөләйман янына җыелды. Аларның алдагылары (аның тарафыннан тәртипләп) арттагылары өчен туктатылалар. Кырмыскалар үзәненә барып җиткәч, бер ана кырмыска: «И, кырмыскалар! Ояларыгызга керегез! Сөләйман һәм аның гаскәрләре сезне абайламыйча таптамасын!» – диде»** («əн-Нәмел», 17–18).

«Хәзрәти Сөләйманның хакимлеге, байлыгы бик зур. Тапталырсыз, ояларыгызга качыгыз!» – ди ана кырмыска. Бу сүзләрне ишеткән Сөләйман галәйһис-сәләәм: «Юк, минем хакимлегем вакытлы гына! Дөньяви тормышым да чикле. Ә бер тәүхид кәлимәсе алып килгән бәхет исә чиксез, мәңгелек!» – дип белдерә.

Аяти кәримәдә болай диелә:

فَتَبَسَّمَ ضَاحِكًا مِنْ قَوْلِهَا وَقَالَ رَبِّ أَوْزِعْنِي أَنْ أَشْكُرَ نِعْمَتَكَ الَّتِي أَنْعَمْتَ عَلَيَّ وَعَلَىٰ وَالِدَيَّ وَأَنْ أَعْمَلَ صَالِحًا تَرْضَاهُ وَأَدْخِلْنِي بِرَحْمَتِكَ فِي عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ

**«(Сөләйман) аның (кырмысканың) сүзләреннән көлә башлап елмайды һәм: “И, Раббым! Миңа һәм ата-анама биргән нигъмәтеңә шөкер итүемне, Син разый булган (изге) бер гамәл эшләвемне миңа илһам ит һәм рәхмәтең белән мине изге колларың арасына керт”, – диде»** («əн-Нәмел», 19).

Аяти кәримәдә әйтелгәнчә, Сөләйман галәйһис-сәләәм бөтен байлыгына, хакимиятенә карамастан, кече күңеллелек һәм буйсынучанлык саклап, үзе белән бергә ата-анасы өчен дә Хак Тәгаләдән рәхмәт өмет итеп, Аңа сыена.

Пәйгамбәр Әфәндебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Сөләйман галәйһис-сәләәмнең әнисенең мондый бер нәсыйхәте турында сөйли: *«Балам! Төннәрен күп йоклама! Чөнки төннәрен күп йоклау кыямәт көнне кешене ярлы калдырыр»* (Ибне Мәҗә, «Икамәтүс-Саләһ», 174/1332).

Шуңа күрә дә, ахирәтнең фәкыйрьләре хәленә калмас өчен, дөнья ләззәтләренә һәм байлыкларына алданмыйча, Хак Тәгаләгә гыйбадәт кылу юлында тырышлык күрсәтү таләп ителә.

**Сөләйман галәйһис-сәләәм, һөдһөд кошы[149] һәм Бәлкыйс**

Сөләйман галәйһис-сәләәм, «әл-Әкъса» мәчетенең төзелеше тәмамлануга, җил, җеннәр, кешеләр, кошлар һәм төрле кыргый хайваннардан оешкан армиясе белән бергә Мәккәгә таба сәфәр кыла. Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезнең Мәккәне шәрәфләндерәчәге турында да хәбәр итә. Аннан Сана шәһәренә юл тота. Күзе төшкән бер матур үзәнлектә намаз укырга тели. Шулчак һөдһөд, алар намаз кылганчы тирә-якта йөреп килү нияте белән, гаскәрдән читкә китә. Анда ул башка һөдһөдләрне очратып, шул кошларга кушыла. Һөдһөд барган җирләрендәге манзараларга хәйран кала. Башка һөдһөдләр аны Бәлкыйс сараеның бакчаларында сәяхәткә дәшә.

Ул вакытта Сөләйман галәйһис-сәләәм , тәһәрәтләнер өчен су тапсын, дип, һөдһөдне эзләргә керешә, чөнки һөдһөдкә тәһарәт өчен су булган урыннарны күрсәтү вазифасы йөкләнгән була.[150] Күпме генә эзләсә дә, Сөләйман галәйһис-сәләәм һөдһөдне таба алмый. Аяти кәримәләрдә бу вакыйга түбәндәгечә сурәтләнә:

وَتَفَقَّدَ الطَّيْرَ فَقَالَ مَا لِيَ لَا أَرَى الْهُدْهُدَ أَمْ كَانَ مِنَ الْغَائِبِينَ

**«(Сөләйман) кошларны эзләде һәм әйтте: “Миңа ни булды? Нишләп һөдһөдне күрмим? Әллә ул югалганнардан булдымы?”»** («ән-Нәмел», 20).

Әүвәл: «Ни булды миңа, ник һөдһөдне күрмим?» – дип, һөдһөдне шәфкать-мәрхәмәт белән эзләгән Сөләйман галәйһис-сәләәм, аның үз яныннан рөхсәтсез китүен, гаскәрендәге дисциплина кагыйдәләре бозылганлыгын белеп алгач, инде болай ди:

لَأُعَذِّبَنَّهُ عَذَابًا شَدِيدًا أَوْ لَأَذْبَحَنَّهُ أَوْ لَيَأْتِيَنِّي بِسُلْطَانٍ مُبِينٍ

**«Аны каты газап белән җәзага дучар итәчәкмен, яки аны чалачакмын, яисә ул миңа ачык дәлил (гафу итәрлек сәбәп) китерәчәк!»** («ән-Нәмел», 21).

149. Һөдһөд – озын нечкә томшыклы, бүрекле кош.

150. Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмә әйтүенчә, һөдһөд кайда су барлыгын белә һәм Сөләйман галәйһис-сәләәмгә су табып бирә торган була. Суның якынмы-еракмы икәнен дә тоя белә. Бу кош су булган җирне томшыгы белән чокый башлый, шуннан соң җеннәр килеп, бу урынны казып су чыгаралар. Ибне Габбаска: «Һөдһөд мондый сәләткә ия булган очракта, бер бала, тозак корып, өстенә бераз туфрак сибеп куйгач, ничек инде кош туфрак астындагы тозакны күрмичә, өстенә китереп баскач, бик җиңел тозакка эләгә соң? Ә үзе хәтта туфрак астындагы суны күрә», – дип әйтәләр. Ибне Габбас радыйаллаһу ганһе: «Када һәм тәкъдирдә язылганның вакыты җиткәч, күзләр күрмәс булыр, акыл баштан чыгар», – дип җавап бирә.

فَمَكَثَ غَيْرَ بَعِيدٍ فَقَالَ أَحَطْتُ بِمَا لَمْ تُحِطْ بِهِ وَجِئْتُكَ مِنْ سَبَإٍ بِنَبَإٍ يَقِينٍ

**«Озак булмаган бервакыт көтте дә (һөдһөд аның янына килеп) әйтте: “Мин син белмәгән бернәрсә турында белдем һәм Сәбәдән сиңа ышанычлы (һәм мөһим) хәбәр китердем”»** («ән-Нәмел», 22).

«Сәбә» Йәмәндә ата-бабаларының исеме белән аталып йөргән бер кабилә була. Сәбә шәһәре Бәлкыйс хакимлек иткән дәүләтнең башкаласы вазифасын үти. Аяти кәримәдә ул кала турында түбәндәгечә телгә алына:

لَقَدْ كَانَ لِسَبَإٍ فِي مَسْكَنِهِمْ آيَةٌ جَنَّتَانِ عَنْ يَمِينٍ وَشِمَالٍ
كُلُوا مِنْ رِزْقِ رَبِّكُمْ وَاشْكُرُوا لَهُ بَلْدَةٌ طَيِّبَةٌ وَرَبٌّ غَفُورٌ

**«Сәбәнең урнашкан урынында билге бар иде. Уң һәм сулдан ике җәннәт (кебек бакчалары бар иде). (Аларга:) “Раббыгызның ризыгыннан ашагыз һәм Аңа шөкер кылыгыз! Бик күркәм шәһәр һәм гафу итүче бер Раббы!” – (дигән идек)»** («Сәбә», 15).

Һөдһөд үзе күргән нәрсәләр турында Сөләйман галәйһис-сәләәмгә сөйләвен дәвам итә:

إِنِّي وَجَدْتُ امْرَأَةً تَمْلِكُهُمْ وَأُوتِيَتْ مِنْ كُلِّ شَيْءٍ وَلَهَا عَرْشٌ عَظِيمٌ

**«Мин бер хатын таптым, ул аларга (сәбәлеләргә) хөкемдарлык итә, һәрнәрсә аңа бирелгән һәм аның зур тәхете бар»** («ән-Нәмел», 23).

وَجَدْتُهَا وَقَوْمَهَا يَسْجُدُونَ لِلشَّمْسِ مِنْ دُونِ اللَّهِ وَزَيَّنَ
لَهُمُ الشَّيْطَانُ أَعْمَالَهُمْ فَصَدَّهُمْ عَنِ السَّبِيلِ فَهُمْ لَا يَهْتَدُونَ

**«Аны һәм кавемен, Аллаһны калдырып, кояшка сәҗдә кылган хәлдә таптым. Шайтан (аларга) гамәлләрен бизәп күрсәткән дә аларны ул юлдан яздырган, шуңа күрә алар һидәят таба алмыйлар»** («ән-Нәмел», 24).

أَلَّا يَسْجُدُوا لِلَّهِ الَّذِي يُخْرِجُ الْخَبْءَ فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ
وَيَعْلَمُ مَا تُخْفُونَ وَمَا تُعْلِنُونَاللَّهُ لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ رَبُّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ

**«Күкләрдә һәм җирдә яшерен булганнарны чыгарган, яшергәннәрегезне дә, ачып күрсәткәннәрегезне дә белгән Аллаһка сәҗдә кылмасыннар, дип, (шайтан әнә шулай эшләде). (Югыйсә) Аллаһ, Аннан башка илаһ юк. Ул – бөек Гарешнең Раббысы»** («ән-Нәмел», 25–26).

قَالَ سَنَنْظُرُ أَصَدَقْتَ أَمْ كُنْتَ مِنَ الْكَاذِبِينَ

**«(Сөләйман һөдһөдкә) әйтте: “Дөресен әйттеңме, әллә ялганладыңмы, тиздән карарбыз!”»** («ән-Нәмел», 27).

Сөләйман галәйһис-сәләәмнең бер мөһере була. Йөзек кашы рәвешендә ясалган бу мөһерне бармагына кигәч, бөтен мәхлуклар Сөләйман галәйһис-сәләәмгә буйсына. Ул йөзеккә «Лә иләһе илләллаһ Мухәммәдүр-Рәсүлүллаһ» дип язылган булуы риваять кылына.

Хәзрәти Сөләйман «бисмилла» белән башланган бер хат яза да, шуңа үзенең атаклы мөһерен басып, һөдһөдкә бирә. Аны кисәтеп куя:

اذْهَبْ بِكِتَابِي هَذَا فَأَلْقِهْ إِلَيْهِمْ ثُمَّ تَوَلَّ عَنْهُمْ فَانْظُرْ مَاذَا يَرْجِعُونَ

**«Шушы хатымны барып, аны аңа ташла, шуннан алардан читкәрәк кит тә кара, җавап итеп нәрсә эшләрләр»** («ән-Нәмел», 28).

Һөдһөд хатны алып, Бәлкыйс тәхетенең өстенә ташлый. Аннары, бер читкә китеп, ни булачагын күзәтә башлый.

Иртән йокыдан торгач, Бәлкыйс тәхетендәге хатны күреп ала. Аны кем китергәнлеге белән кызыксына, чөнки ишекләр бикле була. Сакчылардан: «Бу хатны кем китерде?» – дип сорый.

Алар исә: «Без ишек төбендә сакта тордык. Эчкә берәү дә кермәде!» – диләр. Шуннан соң Бәлкыйс, гаҗәпләнеп, хатны ачып укый һәм аптырап кала. Шундук кавеменең күренекле кешеләрен җыя да аларга:

قَالَتْ يَا أَيُّهَا الْمَلَأُ إِنِّي أُلْقِيَ إِلَيَّ كِتَابٌ كَرِيمٌ إِنَّهُ مِنْ سُلَيْمَانَ وَإِنَّهُ بِسْمِ اللَّهِ الرَّحْمَٰنِ الرَّحِيمِ

**«Әйтте: “И, олуглар! Бик шәрәфле (әһәмиятле) бер хат ыргытылды миңа. Һичшиксез, ул Сөләйманнан һәм Рахман һәм Рәхим булган Аллаһның исеме[151] белән (башлана)”»** («ән-Нәмел», 29–30).

Кайбер мөфәссирләр Бәлкыйснең, хатка һәм анда язылганнарга шушы сүзләре белән ихтирам күрсәтүе сәбәпле, нәтиҗәдә һидәяткә ирешү аша үзенең дә хөрмәтләнүен телгә ала.

Сихерчеләр дә үз заманында Муса галәйһис-сәләәмгә: «Йә, Муса! Әүвәл син атасыңмы, әллә без атыйкмы?» – дип хөрмәт һәм илтифат күрсәтә һәм ахырда иман белән бүләкләнә.

151. Сүрә башларындагы «бисмилла»лар, имам Әбү Хәнифә, Имам Малик һәм Имам Әхмәд ибне Ханбәл хәзрәтләре фикеренчә, сүрә араларын аеручы ролен үти. Имам Шәфигый хәзрәтләренә күрә, һәрберсе аерым аять булып тора.

Моның киресе исә – Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезнең туры юлга өндәгән хатын алгач, аны ертып җиргә ташлаган, мыскыллаган өчен, Иран Хөсрәвенең мал-мөлкәте, дәүләте бүлгәләнә-тарала, үзе исә авыр язмышка дучар булып, гомере көферлектә, бәдбәхет хәлдә тәмамлана.

Аллаһ дусларыннан Бишри Хафи «Аллаһ» исеме язылган бер кәгазьне җирдән табып алгач, аны чистартып, хуш исләр бөрки һәм өенең иң матур җиренә элеп куя. Мондый хөрмәтле мөнәсәбәте сәбәпле Аллаһ Тәгалә аңа бик зур әҗер-савапларга насыйп кылып, исемен изгеләр арасына кертә.

Бәлкыйс хатны укуын дәвам итә:

أَلَّا تَعْلُوا عَلَيَّ وَأْتُونِي مُسْلِمِينَ

**«(Хәзрәти Сөләйман:) “Миңа карата тәкәбберләнмәгез һәм, мөселманнар буларак, миңа килегез” ( – дип язган)»** («ән-Нәмел», 31).

Сөләйман галәйһис-сәләәм хатындагы «бисмилла» белән Бәлкыйскә гыйбадәтләрнең бары бердәнбер Аллаһка гына кылу тиешлеген белдерә. Шул рәвешле хак игътикадны аңлатканнан соң: «Миңа карата тәкәбберлек күрсәтмәгез!» – дип кисәтеп, нәфесләрен кулга алырга өнди һәм “Минем яныма мөселман булып килегез!” дип чакыра. Шулай итеп Сөләйман галәйһис-сәләәм бөтен бәхетнең исламда икәнлеген ачып бирә.

قَالَتْ يَا أَيُّهَا الْمَلَأُ أَفْتُونِي فِي أَمْرِي مَا كُنْتُ قَاطِعَةً أَمْرًا حَتَّىٰ تَشْهَدُونِ قَالُوا نَحْنُ أُولُو قُوَّةٍ وَأُولُو بَأْسٍ شَدِيدٍ وَالْأَمْرُ إِلَيْكِ فَانْظُرِي مَاذَا تَأْمُرِينَ

**«(Аннары патшабикә Бәлкыйс) әйтте: “И, олуглар! Эшем хакында миңа киңәш бирегез, (беләсез) сез минем янымда булганчыга кадәр, мин (сезнең белән киңәшмичә) бер эшкә дә кискен хөкем биргән кеше булмадым”. (Алар) әйттеләр: “Без зур куәткә иябез, көчле каһарманлык ияләребез, ләкин әмер – синеке. Нәрсә әмер иткәнеңне кара!”»** («ән-Нәмел», 32–33).

قَالَتْ إِنَّ الْمُلُوكَ إِذَا دَخَلُوا قَرْيَةً أَفْسَدُوهَا وَجَعَلُوا أَعِزَّةَ أَهْلِهَا أَذِلَّةً وَكَذَٰلِكَ يَفْعَلُونَ

**«(Патшабикә Бәлкыйс) әйтте: «Хөкемдарлар берәр мәмләкәткә килгән чакта, харап итәләр һәм аның халкының олугларын түбән хәлгә китерәләр. Алар һәрвакыт шулай итәләр. Мин (хәзер) аларга бүләкләр җибәрәчәкмен һәм җибәрелгәннәрнең (илчеләрнең) ни (нинди нәтиҗә) белән кайтканнарын караячакмын»** («ән-Нәмел», 34–35).

Һөдһөд китергән хат аша Сөләйман галәйһис-сәләәмнән: «Миңа каршы баш күтәрмәгез; буйсынучанлык күрсәтеп, минем яныма килегез!» – дигән хәбәр алган Бәлкыйс, бу хәл турында кавеменең алдынгы затлары белән, ягъни белгечләр шурасы белән киңәшләшә, нәтиҗәдә Сөләйман галәйһис-сәләәмгә илчеләр җибәреп, аңа кыйммәтле бүләкләр тәкъдим итәргә, шул рәвешле пәйгамбәрнең явыннан котылып калырга карар чыгарыла.

Сөләйман галәйһис-сәләәм исә үзен бүләкләр ярдәмендә аны юмаларга тырышуларын аңлый һәм, әлеге бүләкләрне бер ришвәт дип кабул итеп, катгый кисәтү-янау белән, аларны кире борып җибәрә:

فَلَمَّا جَاءَ سُلَيْمَانَ قَالَ أَتُمِدُّونَنِ بِمَالٍ فَمَا آتَانِيَ اللَّهُ خَيْرٌ مِمَّا آتَاكُمْ بَلْ أَنْتُمْ بِهَدِيَّتِكُمْ تَفْرَحُونَ

**«(Илчеләр бүләкләр белән) Сөләйманга килгәч, ул (аларга) әйтте: “Сез миңа мал белән ярдәм итәсезме әллә? Аллаһ миңа биргән нәрсәләр сезгә биргәннәрдән өстенрәк. Бүләкләрегезгә сез үзегез генә сөенәсез”»** («ән-Нәмел», 36).

ارْجِعْ إِلَيْهِمْ فَلَنَأْتِيَنَّهُمْ بِجُنُودٍ لَا قِبَلَ لَهُمْ بِهَا وَلَنُخْرِجَنَّهُمْ مِنْهَا أَذِلَّةً وَهُمْ صَاغِرُونَ

**«(Әй, илче!) Аларга кайт, һичшиксез, алар каршы тора алмаслык гаскәр белән аларга барырбыз, аларны кимсетелгән һәм хур ителгәннәр буларак аннан чыгарырбыз!»** («ән-Нәмел», 37).

Илчеләр, патшабикә янына кайтып, Сөләйман галәйһис-сәләәмнең әйткәннәрен тапшыргач, Бәлкыйс: «Ниятебезне аңлаган булса кирәк! Валлаһи, бу бер фәрештә генә түгел; без аңа каршы тора алмаячакбыз!» – ди дә: «Кавемнең олуг затлары белән аның каршына киләм. Аның хакимлеген һәм ул өндәгән динне күрергә телим!» – дигән хәбәр белән тагын бер илче җибәрә.

Бәлкыйс мәшһүр тәхетен, сарайларының иң ныклы һәм яхшы сакланган бер бүлмәсенә урнаштырып, ишекләрне бикләттерә. Аннары бик зур төркем белән Сөләйман галәйһис-сәләәм янына юл тота.

Шулвакытта Сөләйман галәйһис-сәләәм үз янындагыларга Бәлкыйснең Сәбәдәге тәхетен алып килергә куша. Бу әмеренең максаты, мөфәссирләр фикеренчә, түбәндәгедән гыйбарәт була:

1. Бәлкыйс өчен Аллаһның кодрәтенә һәм үзенең пәйгамбәрлегенә дәлил булырлык бер могҗиза һәм әүвәлге дәлилләргә өстәп, яңа бер дәлил күрсәтү.

2. Китерткән тәхетне алыштырып куеп, аны таныймы-юкмы икәне мәсьәләсендә Бәлкыйснең зирәклеген сынау.

3. Тәхет бер патшалык символы булып тора. Бәлкыйс килгәнче, аның патшалыгының ни хәлдә, ни дәрәҗәдә икәнлеген белешү (Фәхреддин әр-Разый, «Тәфсир», XXIV том, 169 б.).

قَالَ يَا أَيُّهَا الْمَلَأُ أَيُّكُمْ يَأْتِينِي بِعَرْشِهَا قَبْلَ أَنْ يَأْتُونِي مُسْلِمِينَ

قَالَ عِفْرِيتٌ مِنَ الْجِنِّ أَنَا آتِيكَ بِهِ قَبْلَ أَنْ تَقُومَ مِنْ مَقَامِكَ وَإِنِّي عَلَيْهِ لَقَوِيٌّ أَمِينٌ

**«(Сөләйман киңәшчеләренә) әйтте: “И, олуглар! Алар миңа (буйсынып) мөселманнар хәлендә килмәс борын, миңа аның тәхетен кайсыгыз алып килә?”» Җеннәрдән бер гыйфрит[152] әйтте: «Син урыныңнан тормас борын, мин аны сиңа алып килермен, мин бит моңа бик көчле һәм ышанычлымын»** («ән-Нәмел», 38–39).

Сөләйман галәйһис-сәләәм иртән тәхетенә утыра, дөнья эшләре һәм идарә мәшәкатьләре белән шөгыльләнә, өйләгә таба тәхетеннән тора. Шуңа күрә гыйфрит Бәлкыйс тәхетен таң белән өйлә арасындагы бер вакытта алып килә алачагын сөйли.

قَالَ الَّذِي عِنْدَهُ عِلْمٌ مِنَ الْكِتَابِ أَنَا آتِيكَ بِهِ قَبْلَ أَنْ يَرْتَدَّ إِلَيْكَ طَرْفُكَ فَلَمَّا رَآهُ مُسْتَقِرًّا عِنْدَهُ قَالَ هَذَا مِنْ فَضْلِ رَبِّي لِيَبْلُوَنِي أَأَشْكُرُ أَمْ أَكْفُرُ وَمَنْ شَكَرَ فَإِنَّمَا يَشْكُرُ لِنَفْسِهِ وَمَنْ كَفَرَ فَإِنَّ رَبِّي غَنِيٌّ كَرِيمٌ

**«Янында китаптан (Аллаһ тарафыннан бирелгән) гыйлеме булган кеше: “Карашың сиңа кире кайтмас борын, мин аны алып килермен”, – диде. Ул (Сөләйман) аны (патшабикәнең тәхетен) янында урнашкан хәлдә күргәч: “Бу шөкер итәрме, әллә шөкерсезлек кылырмы, дип, мине сынау өчен, Раббымның фазылыннан. Кем дә кем шөкер итсә, үзе өчен шөкер иткән булыр, кем дә кем шөкерсезлек кылса, һичшиксез, минем Раббым – Бай, Юмартларның юмарты”, – диде»** («ән-Нәмел», 40).

Ныклы дәлилле карашка күрә, тәхетне күз ачып йомганчы алып килерлек гыйлемгә ия зат Сөләйман галәйһис-сәләәмнең вәзире Асаф ибне Бәрхия була.

### Кәрамәт

Әүлияларда күзәтелә торган кәрамәтләрне, ягъни гайре табигый сыйфатларны һәм метафизик күренешләрне ике төркемгә аералар:

1. Аллаһ Җәллә Җәләлүһүнең затына, сыйфатына һәм гамәлләренә караган билгеләр. Аларны башка төрле «кәшеф» дип тә атыйлар. Бу билгеләрне акыл белән яисә фикерләү аша үзләштерү мөмкин түгел. Аллаһ Тәгалә андый сыйфатларны үзе сайлаган колларына гына насыйп итә.

152. Гыйфрит – «куәтле, оста, тоткан җирдән әйләндереп салучы, тиктормас, буйсынмас» дигән мәгънә белдерә. Шулай ук «яманлыкта һәм кяферлектә бик алдынгы, шайтанлыкта оста» дигән мәгънәгә дә ия. Бу сүз кешеләр өчен кулланылганга, аятьтә «җеннәрдән бер гыйфрит» рәвешендә аныклап бирелә.

2. Матди галәмдә барлыкка килә торган гайре табигый күренешләр. Боларын да Аллаһ Тәгалә үзе сайлаган колларга ирештерә.

Кешеләр икенче төркемдәгеләргә – гайре табигый күренешләргә игътибар итә. Чынлыкта исә беренчесе хуплана. Имам Шәфигый: «Имам Муса Казыйм кабере янында укыган догамның кабул булуына күнектем. Моны берничә тапкыр сынап карадым», – дип әйтә. Имам Газали Хәзрәтләре: «Тере чагында фазыйләт килгән заттан, тәвәссүл ярдәмендә үлеменнән соң да бәрәкәт алыныр!» – дигән.

Җәнабел-Хак үлемнән соң да бик зур йогынты ясау мөмкинлеге биргән әүлиялардан Мәгъруфи Кәрхи һәм Габделкадыйр Гәйлани Хәзрәтләре аеруча билгеле. Кәрамәт күренешләре вакыт-вакыт әсхабе кирам арасында да күзәтелә. Әйтик, һиҗрәтнең егерме өченче елында иранлылар белән сугыш вакытында Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһе Мәдинәи Мөнәввәрәдә мөнбәрдән: «Әй Сария! Тауга, тауга!» – дип, Хәзрәти Сарияне һәм аның янындагы ислам гаскәрен куркыныч янау турында кисәтә һәм алар Хәзрәти Гомәрне ишетә (Ибне Һаҗәр, «әл-Исабә», II, 3).

Әнәс радыйаллаһу ганһе сөйләгәннәрдән:

«Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләреннән ике кеше (Үсәйд ибне Худайр һәм Габбад ибне Бәшир) караңгы төндә Рәсүлүллаһ галәйһис-сәләәм яныннан чыкты. Каршыларында факел кебек ике ут барлыкка килде. Алар бер-берсеннән аерылгач та, өйләренә кайтып җиткәнче, һәркайсының юлын бер ут яктыртып бара (Бохари, «Сaләт», 79; «Мәнакыйбүл-Әнсар», 13).

Имам Гали Риза рәхмәтуллаһи галәйһи бер дивар янында утырып тора. Шулчак бер кош килеп сайрый башлый. Имам Гали Риза рәхмәтуллаһи галәйһи үз янындагыларга: «Бу кош аның оясына бер елан якынаю турында сөйли һәм: “Балаларымны коткарыгыз!” – дип ярдәм сорый» – ди. Барып карасалар, ни күрсеннәр – чыннан да кош оясына бер елан һөҗүм иткән. Кош балаларын коткару өчен, шундук еланны үтерәләр.

Бәлкыйс тәхете Сөләйман галәйһис-сәләәм могҗизасы белән түгел, ә Асаф ибне Бәрхиянең кәрамәте ярдәмендә китерелә. Бу исә Сөләйман галәйһис-сәләәмнең рухи өстенлеген, бөеклеген күрсәтә, чөнки Асаф ибне Бәрхия Сөләйман галәйһис-сәләәмнең вәзире була.

قَالَ نَكِّرُوا لَهَا عَرْشَهَا نَنْظُرْ أَتَهْتَدِي أَمْ تَكُونُ مِنَ الَّذِينَ لَا يَهْتَدُونَ

**«(Сүзен дәвам итеп, Сөләйман) әйтте: “Аның өчен тәхетен танымаслык хәлгә кертегез, карарбыз, турыны таба алырмы, әллә турыны таба алмаучылардан булырмы?”»** («ән-Нәмел», 41).

Тәхетне бик тиз арада алып киләләр. Моны күз ачып йомганчы мизгел дип әйтергә мөмкин. Югыйсә, тәхет китерелгән җир белән ике арадагы ераклык, бер карашка күрә, өч көнлек (Сәбә белән Сана арасы), бер риваятькә күрә, ике айлык (Сәбә белән Димәшкъ арасы) юл тәшкил итә, башка бер фикергә күрә исә, Сәбә белән Иерусалим арасындагы юл кадәр була. Тәхетнең шулкадәр тиз китерелүе гадәти бер вакыйга түгел, ә бер кәрамәт күренеше булып тора.

فَلَمَّا جَاءَتْ قِيلَ أَهَكَذَا عَرْشُكِ قَالَتْ كَأَنَّهُ هُوَ وَأُوتِينَا الْعِلْمَ مِنْ قَبْلِهَا
وَكُنَّا مُسْلِمِينَ وَصَدَّهَا مَا كَانَتْ تَعْبُدُ مِنْ دُونِ اللَّهِ إِنَّهَا كَانَتْ مِنْ قَوْمٍ كَافِرِينَ

**«Ул (Бәлкыйс) килгәч, әйтелде: “Синең тәхетең дә моның кебекме?” Ул: “Гүяки бу ул! Моннан алда безгә (Аллаһтан) гыйлем бирелгән иде дә, без мөселманнар булган идек”, – диде (Ягъни Җәнабел-Хакның кодрәте һәм Хәзрәти Сөләйманның пәйгамбәрлеге мәсьәләсендә әүвәлрәк булган вакыйгалар да безне ышандырган, фикер тудырган иде). Әмма Аллаһны калдырып, табынган нәрсәсе аңа (шушы вакытка кадәр тәүхид дингә керергә) комачаулаган иде, чөнки, һичшиксез, ул кяферләр булган бер кавемнән иде»** («ән-Нәмел», 42–43).

فَلَمَّا جَاءَتْ قِيلَ أَهَكَذَا عَرْشُكِ قَالَتْ كَأَنَّهُ هُوَ وَأُوتِينَا الْعِلْمَ مِنْ قَبْلِهَا وَكُنَّا مُسْلِمِينَ
وَصَدَّهَا مَا كَانَتْ تَعْبُدُ مِنْ دُونِ اللَّهِ إِنَّهَا كَانَتْ مِنْ قَوْمٍ كَافِرِينَ

**«Аңа: “Сарайга кер!” – дип әйтелде. Ул аны күргәч, аны тирән су дип уйлады да (итәген күтәреп) балтырларын ачты. Ул (Сөләйман): “Бу бәллүрдән шомартып төзелгән сарай (үтәкүренмәле идән) бит”, – диде. Ул (патшабикә) әйтте: “И, Раббым! Мин үз-үземә золым эшләдем. Сөләйман белән бергә бөтен галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка буйсынам”»** («ән-Нәмел», 44).

Риваятькә күрә, Хәзрәти Сөләйман Сәбә патшабикәсе Бәлкыйс килгәнче бер сарай төзетә. Бу сарайның эчке ачык ишегалды бәллүрдән ясала, ә аның астына су кертелә. Суга балыклар җибәрелә. Идәннең үтәкүренмәле каты нәрсәдән икәнен аңламыйча, судан үтәргә туры килә, дип уйлап, Бәлкыйс итәген күтәрә. Шундый барлык ысул-чаралар аның үз акылына һәм белемнәренә ышанычын какшата, күңелен илаһи гыйлемне кабул итәргә хәзерли. Шул рәвешле Бәлкыйс, боларның кешегә хас күренеш түгеллеген төшенеп, бу эшләрдә илаһи бөеклекне күрә һәм мөселман була.

**Сөләйман галәйһис-сәләамнең үлеме**

Үлем килгән мизгелдә Хәзрәти Сөләйман галәйһис-сәләам таякка таянып торган була. Аягөсте басып торганлыктан, аның вафатын әйләнә-тирәсендәгеләрдән һичкем сизми кала. Бер агач корты таякны ашап, Хәзрәти Сөләйман

җиргә егылып төшкәч кенә, аның үлгәнлеге аңлашыла. Аяти кәримәдә бу хакта болай диелә:

قِيلَ لَهَا ادْخُلِي الصَّرْحَ فَلَمَّا رَأَتْهُ حَسِبَتْهُ لُجَّةً وَكَشَفَتْ عَنْ سَاقَيْهَا قَالَ إِنَّهُ صَرْحٌ مُمَرَّدٌ مِنْ قَوَارِيرَ قَالَتْ رَبِّ إِنِّي ظَلَمْتُ نَفْسِي وَأَسْلَمْتُ مَعَ سُلَيْمَانَ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Шуннан аңа үлемне хөкем иткән чагыбызда, аның (Сөләйманның) үлгәнен аларга аның таягын ашаган җирдәге җанлы (агач корты) күрсәтте. Ул (соңыннан) егылгач, җеннәр аңлады ки, әгәр алар гаибне белгән булсалар, кимсетүле газап эчендә көтмәсләр иде»** («Сәбә», 14).

Сөләйман галәйһис-сәләәм үлгәч, җәсәденең озак кына вакыт таякка таянган хәлдә аягөсте калуы аңлашыла. Аяти кәримәдә җеннәр турында әйтелгән «түбәнлеккә төшерә торган газап» тәгъбире аларның авыр эшләрдә кулланылуына нигезләнеп кулланылган. Сөләйман галәйһис-сәләәмнең үлгәнлеген белмәгәч, ул исән чактагы кебек, җеннәр шул читен эшләрен дәвам итә. Моннан исә җеннәрнең яшерен нәрсәләрне белмәве аңлашыла.

Сөләйман галәйһис-сәләәмнең тормышы кебек, үлеме дә тәүхидкә өндәү сыйфатына ия була, чөнки ул үзенең вафаты белән, Аллаһтан башка һичбер мәхлукның яшерен нәрсәне белә алмаячагын, бары Җәнабел-Хак белдергәннән соң гына, моны аерып булганын күрсәтә. Җәнабел-Хак, Сөләйман галәйһис-сәләәмнең үлемен кечкенә, көчсез мәхлук булган агач корты ярдәме белән ачып күрсәтеп, яшерен нәрсәләрдән хәбәрдар булуларын расларга маташкан җеннәрнең дә Аллаһның ихтыярыннан башка һичнәрсә белә алмаячакларын ап-ачык бәян кыла.

Башка яктан караганда, шулкадәр зур байлык һәм хакимияткә ия Сөләйман галәйһис-сәләәмнең аягүрә үлүе бик тирән уйларга этәрә торган күренеш һәм бик зур гыйбрәт булып тора. Нигездә, бөтен пәйгамбәрләрнең әйткән сүзләре, гомерләре һәм аларның башларыннан кичкән вакыйгалар үзләреннән соң килгән барлык өммәтләр өчен гыйбрәт чыганагы, дип әйтергә мөмкин.

Дөньяның фанилыгы һәм хәтта Сөләйман галәйһис-сәләәмнең бөек патшалыгының да вакытлылыгы үгет-нәсыйхәт, гыйбрәтле хикәяткә әверелә. Зия Паша атаклы «Тәркиб бәнде»ндә болай ди: «Күзәтте теләгәнчә тәхетеннән Сөләйман, ул патшалыкның җилләр исә хәзер урынында!..»

Юныс Әмрә Хәзрәтләренең менә мондый дүртьюллыгы канатлы гыйбарәгә әйләнгән:

«Мал хуҗасы, мөлкәт хуҗасы.
Кая моның тәүге хуҗасы?
Мал да ялган, мөлкәт тә ялган.
Бар син дә бераз тоткарлан!..»

**Хакимлек һәм кече күңеллелек**

Сөләйман галәйһис-сәләәм бик түбәнчелекле, кече күңелле була. Иртән торуга, ул фәкыйрьләр һәм ятимнәр-ялгызлар янына барып: «Фәкыйрьгә фәкыйрьләр янында булу килешә!» – дип, шулар янында утыра.

Халыкта Сөләйман галәйһис-сәләәм белән чыпчык арасында булган гыйбрәтле вакыйга риваять кылына. Бервакыт Сөләйман галәйһис-сәләәм бер чыпчыкны (яки һөдһөд кошын) ачулана. Моңа каршы чыпчык Сөләйман галәйһис-сәләәмгә: «Синең патшалыгыңны һәм сараеңны җимерермен!» – дип яный.

Сөләйман галәйһис-сәләәм: «Шундый кечкенә авырлыгың белән син сараемны җимерәм, диясеңме!» – дип аптырый.

Кошчык болай дип җавап бирә: «Канатларымны чылатырмын да вакф туфрагына сылармын. Аннары канатларыма буялган вакф туфрагын сараеңның түбәсенә ташлармын. Шулай итеп мин ташыган ул вакф туфрагы синең сараеңны җимерергә җитәр!»

Бу кыйссадан сабак буларак, вакф малларының никадәр әһәмиятле икәнлеген төшенеп, аларга карата мөмкин кадәр игътибарлы һәм гадел мөнәсәбәт сакларга кирәклеген күзалларга тиешбез. «Вау»лардан (ягъни «валлаһи» дип кирәксез урында ант итүдән, җавапсыз, игътибарсыз җитәкче (вәли), ятимне, авыруны тәрбияләргә алынып та, вазифасын үтәми торган зат (васи) булудан һәм вакф малына хыянәт кылудан) сакланыгыз!» – дип галимнәр юкка гына әйтмәгән.

Мондагы тыелуда максат әлеге оешмаларда эшләүчеләрнең хак-хокукларның үтәлүенә игътибар бирергә кирәклеге, чөнки күчемле һәм күчемсез милек була алган вакф малын үзләштерү һәм читләштерү тыела, ул – Аллаһ Тәгаләнеке, файдасы исә өммәтнеке булырга тиеш.

Кайбер чыганакларда Сөләйман галәйһис-сәләәмнең җәннәткә башка пәйгамбәрләрдән биш йөз ел соңрак керәчәге риваять кылына. Чөнки Хәзрәти Сөләйманга бик зур патшалык һәм байлык бирелә. Боларның бөтенесе өчен хисап бирүнең озакка сузылачагы аркасында, аның җәннәткә бүтән пәйгамбәрләрдән соң гына керәчәге белдерелә.[153] Аяти кәримәдә пәйгамбәрләргә дә хисап тотарга туры киләчәге телгә алына:

فَلَنَسْأَلَنَّ الَّذِينَ أُرْسِلَ إِلَيْهِمْ وَلَنَسْأَلَنَّ الْمُرْسَلِينَ

**«Һичшиксез, үзләренә (пәйгамбәр итеп) җибәрелгән кешеләрдән сораячакбыз. Һичшиксез, җибәрелгән кешеләрдән дә (пәйгамбәрләрдән дә) сораячакбыз (хисап алачакбыз)!»** («әл-Әгъраф», 6).

153. Карагыз: Куртуби, «Тәфсир», XV, 204.

### Хәзрәти Сөләйманнан соң

Унике кабиләдән оешкан Бәни Исраил Сөләйман галәйһис-сәләамнән соң икегә аерыла. Ун кабиләдән Исраил (Израиль) дәүләте, ике кабиләдән исә Яһуда дәүләте корыла. Ун кабиләдән оешкан Исраил дәүләтен б.э. кадәр 721 елда ассирияләләр тар-мар итә. Ике кабиләдән оешкан Яһуда дәүләтен исә б.э. кадәр 586 елда Вавилон патшасы Бухтүннаср (Навуходоносор) җимерә. Бухтүннаср Бәйтүл-Макдисне дә яндыра, халкының күбесен үтерә. Калганнарын Вавилонга алып китә. Бу залим Нәмрудтан соң дөнья белән хакимлекне кулга төшергән икенче имансыз патша була. Вавилонны төзетеп, аны иленең башкаласына әйләндерә. Көнчыгыш һәм Көнбатышта үзенә каршы торырлык һичкемне калдырмый. Шул рәвешле тәкәбберлеккә бирелеп, үзен тәңре дип игълан итә. Ахыр чиктә акылын тәмам җуеп, үзен үгез дип күз алдына китерә башлый. Җиде ел урманнар гизеп йөри. Ул вакытта патшалыгы белән хатыны идарә итә. Вафатына бер ел кала акылы кире кайтарыла, патшалыгын янә кулга алуы риваять кылына.

Бухтүннаср Иерусалим шәһәрен күп тапкыр җимерә. Тәүрат һәм Зәбурны яндырып, юкка чыгара. Шулай итеп, вакытлар узу белән, Тәүратның шактый бүлекләре табигый рәвештә онытыла. Хәтердә калганнары язып теркәлә башланганда исә, Тәүрат асыл мәгънәсен тулысынча югалта, бер-берсенә бәйләнмәгән, төрле хикәятләр генә барлыкка килә. Якынча б.э. кадәр 500 нче елларда яшәгән Әзра (Гозәер) язулы хәлдәге бу Тәүратларны туплый. Ул гыйбадәтханәне икенче тапкыр төзүдә катнаша. Бүгенге яһүди тәгълиматына күрә, ул чорга кадәр тулысынча югалган булган Тәүратны Яһуда алла Әзрага вәхи аша кабат яздыра.

Иран патшасы Нүшәк (Куруш яки Кир), вавилонлыларны җиңгәч, Бәни Исраилнең яңадан Иерусалимгә кайтуына рөхсәт бирә. Исраил угыллары б.э. кадәр 515 елда «әл-Әкъса» мәчетен төзекләндерәләр. Алар әүвәл фарсылар, аннары македонияләләр кул астында яши. Б.э. 63 елында римлылар яулап алып, яһүдиләрне кабат тараталар. «Әл-Әкъса» мәчете харап ителә.

Исраил угылларының бу кадәр бәла-казаларга дучар ителүе үз азгынлыклары белән бәйле. Алар шундый бозыклыклары аркасында, нәфесләренә туры килмәгәнгә күрә, Тәүрат һәм Зәбурны үзгәртәләр, шул рәвешле хак динне бозалар. Мондый эш-гамәлләргә комачауларга теләгән Зәкәрийя галәйһис-сәләам һәм Яхъя галәйһис-сәләам кебек кайбер пәйгамбәрләрне дә, һич кансыз-кызганусыз рәвештә, кыргыйларча үтерәләр.

### Һарут белән Марут кыйссасы

Яһүдиләр арасында сихерчелек киң таралган була. Шунлыктан Хәзрәти Сөләйманның бик зур сихерче булуы, хөкемдарлыкны да сихер ярдәмендә кулга төшерүе, хайваннарны һәм җеннәрне тылсым белән буйсындыруы

турында сөйләп йөриләр һәм моңа үзләре дә ышаналар. Хәзрәти Сөләйманның Коръәни-Кәримдә пәйгамбәр икәнлеге танытылгач: «Мөхәммәд Сөләйманны пәйгамбәр дип саный, ә чынлыкта ул бер тылсымчы!» – дип каршы чыгалар. Шуннан соң түбәндәге аяти кәримә иңдерелә:

وَاتَّبَعُوا مَا تَتْلُو الشَّيَاطِينُ عَلَىٰ مُلْكِ سُلَيْمَانَ وَمَا كَفَرَ سُلَيْمَانُ وَلَٰكِنَّ الشَّيَاطِينَ كَفَرُوا يُعَلِّمُونَ النَّاسَ السِّحْرَ وَمَا أُنْزِلَ عَلَى الْمَلَكَيْنِ بِبَابِلَ هَارُوتَ وَمَارُوتَ وَمَا يُعَلِّمَانِ مِنْ أَحَدٍ حَتَّىٰ يَقُولَا إِنَّمَا نَحْنُ فِتْنَةٌ فَلَا تَكْفُرْ فَيَتَعَلَّمُونَ مِنْهُمَا مَا يُفَرِّقُونَ بِهِ بَيْنَ الْمَرْءِ وَزَوْجِهِ وَمَا هُمْ بِضَارِّينَ بِهِ مِنْ أَحَدٍ إِلَّا بِإِذْنِ اللَّهِ وَيَتَعَلَّمُونَ مَا يَضُرُّهُمْ وَلَا يَنْفَعُهُمْ وَلَقَدْ عَلِمُوا لَمَنِ اشْتَرَاهُ مَا لَهُ فِي الْآخِرَةِ مِنْ خَلَاقٍ وَلَبِئْسَ مَا شَرَوْا بِهِ أَنْفُسَهُمْ لَوْ كَانُوا يَعْلَمُونَ

**«Алар Сөләйманның падишаһлыгы (чорында) шайтаннарның укып йөргән нәрсәләренә ияргәннәр. Тик Сөләйман (сихер ясаган) кяфер түгел иде, кешеләргә сихерне һәм Бабил илендәге ике фәрештәгә – Һарут белән Марутка иңдерелгән нәрсәне өйрәтеп, шайтаннар кяфер булдылар. Хәлбуки, ул икәү (фзрештәләр): “Без сезгә фетнә (сынау өчен) бит, сез (ялгыш ышанып) кяфер булмагыз!” – дип әйтми торып, беркемне дә (сихер гыйлеменә) өйрәтмиләр иде. Алар ир белән хатын арасын аера торган нәрсәләрне шул икәүдән (ике фәрештәдән) өйрәнгәннәр иде, тик алар (сихерчеләр), Аллаһның рөхсәте булмыйча, аның белән һичкемгә дә зарар китерә алмаячаклар. Алар үзләренә зарар китергән, бер дә файда китермәгән нәрсәне өйрәнәләр иде. Шиксез, алар моны (сихерне) сатып алган кешегә (аңа ышанып, акча бирүчеләргә) ахирәттә бернинди өлеш юклыгын яхшы беләләр иде. Җаннары хисабына сатып алган нәрсәләре яман! Әгәр (моны) белсәләр иде!»** («әл-Бәкара», 102).

Мөфәссир Фәхреддин әр-Разый Һарут белән Марут исемле ике фәрештәнең җир йөзенә төшерелү сәбәбен болай аңлата:

а) Бу ике фәрештә җиргә иңдерелгән чорда, сихерчеләр күбәйгән була. Ул тылсымчылар, сихер өлкәсендә моңарчы һичкем белмәгән нәрсәләрне күрсәтеп, үзләрен пәйгамбәр дип расларга маташалар. Шулай итеп, үзләренең кешеләрдән өстен икәнлекләрен белдерәләр. Шул сәбәпле Аллаһ Тәгалә, үзләрен пәйгамбәр дип атаган бу ялганчыларны кешеләр аера белсен, танысын өчен, аларга каршы торырлык сихер серләрен өйрәтү максатында Һарут белән Марутны җибәрә.

б) Могҗизаның сихердән аерылганын аңлау могҗиза белән сихернең нәрсә икәнлеген белүгә бәйле. Асылда, кешеләр ул чорда сихернең асылын, сыйфатын белмиләр. Димәк, алар могҗизаның да хикмәтен белә алмый. Шун-

нан соң Аллаһ Тәгалә, кешеләргә сихернең асылын аңлатсыннар да, могҗизаның хикмәте ачылсын дип, Һарут белән Марутны җибәрә.

в) Башка бер фикергә күрә, Аллаһның дошманнары арасын бозган, дуслары арасында мәхәббәтне үстергән сихер кешеләр өчен мөбаһ яки мәндуб (хуплана торган) гамәл санала. Шуңа күрә Аллаһ Тәгалә, шундый максатларда сихергә өйрәтсеннәр дип, әлеге ике фәрештәне җибәрә. Кызганыч, ул заман кешеләре бу ике фәрештәдән өйрәнгән ак (яхшы ниятле) сихерне соңыннан яман максатларда, ягъни Аллаһның дуслары арасына дошманлык кертү һәм Аның дошманнары арасында мәхәббәт булдыру рәвешендә бөтенләй капма-каршы һәм ялгыш юнәлештә куллана башлыйлар.

г) Сихер тыелганга күрә, аның бәндә өчен таныш һәм күз алдына китерерлек нәрсә булуы таләп ителә, чөнки хәтта күз алдына китереп булмас нәрсәләрнең тыелуы аңлашылмас иде.

д) Ихтимал, җеннәр кешеләр кыла алмаслык төрледән-төрле сихерләрне белгәннәрдер. Җәнабел-Хак җеннәргә каршы тора алырлык сихер серләрен кешеләргә өйрәтсеннәр өчен, Һарут белән Марутны җибәрә.

е) Бу вакыйга бәндә өчен илаһи коллык бурычларын кыенлаштырган бер сынау дип тә карала ала, чөнки кешенең үзен дөнья ләззәтләренә ирештерәчәк берәр нәрсәне өйрәнгәннән соң, бу нәрсәдән тыелып торуы тагын да авыррак. Сынау кыенлашкан саен, ул сынауны уңышлы үтеп чыгучыларга әҗере дә шулкадәр үк күбрәк булыр. Шунлыктан кеше, тыелганнан тыелып, тагын да күбрәк әҗер-савапка ирешә ала.

Хак Тәгалә Талутның кавемен, сугышка барганда, эссе көнне елгадан су эчү мәсьәләсендә сыный. Илаһи әмергә ярашлы рәвештә, Талут:

إِنَّ اللّٰهَ مُبْتَلِيكُمْ بِنَهَرٍ فَمَنْ شَرِبَ مِنْهُ فَلَيْسَ مِنِّي وَمَنْ لَمْ يَطْعَمْهُ فَإِنَّهُ مِنِّي

**«…Кем дә кем аннан (ул елгадан туйганчы) эчә, ул – миннән түгел. Кем дә кем аны (рөхсәт ителгәннән артык) татымый, кулы белән бер уч чумырып кына ала, һичшиксез, ул – миннән...»** – дип шарт куя («әл-Бәкара», 249).

Кыскасы, бөтен аңлатмалардан Аллаһ Тәгаләнең ул фәрештәләрне сихергә өйрәтер өчен җибәрүендә бик күп хикмәтләр булуы турында нәтиҗә ясарга мөмкин. Һичшиксез, Аллаһ Тәгалә – һәр эштә хикмәт иясе һәм һәрнәрсәне иң яхшы белүче.

### Рәсүлүллаһ Әфәндебезнең Хәзрәти Сөләйманнан өстенлеге

1. Сөләйман галәйһис-сәләамгә җилләр буйсындырыла. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә исә олылы-кечеле барлык фәрештәләр хезмәт итә.

2. Сөләйман галәйһис-сәләәм бер көндә ике айлык юл уза. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мигъраҗ кичәсендә бер мизгел эчендә гарешкә күтәрелә.

3. Сөләйман галәйһис-сәләәмгә кошлар күләгә ясый. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең исә болыт күләгәсендә йөргәнлеге әйтелә.

4. Сөләйман галәйһис-сәләәмнең кул астында хезмәт куяр өчен, бөтен мәхлуклар туплана. Кыямәт көнне бөтен пәйгамбәрләр, әүлиялар, шәһидләр һәм изгеләр Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең «Лива әл-Хәмед» дип аталган байрагы астында җыелачак.

5. Сөләйман галәйһис-сәләәмгә бөтен дөнья мөлкәте-байлыгы бирелә. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтеннән һәркемгә исә җәннәттә бу дөньядагыдан ун тапкыр зуррак патшалык насыйп кылына (Мөслим, «Иман», 308; Тирмизи, «Җәһәннәм», 10).

6. Сөләйман галәйһис-сәләәмгә «көрси» бирелә. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә «Аятел-көрси» иңдерелә. «Аятел-көрси» җәннәт хәзинәләреннән булып тора; аннан шайтаннар кача.

# БАР МӨЛКӘТ – АЛЛАҺНЫКЫ

Аллаһ Тәгалә, пәйгамбәрләр арасыннан байлык иясе буларак Сөләйман галәйһис-сәләәмне мисал итеп китерә, чөнки Сөләйман галәйһис-сәләәм үзенә насыйп кылынган дөнья байлыгына йөрәген яулап алырга һичвакыт юл куймый. Бөтен кешеләр берләшеп көч куеп, берәр кешене Сөләйман галәйһис-сәләәм хәтле баетырга тырышсалар да, бу һич чынга аша алмас, чөнки җилләр, хайваннар, богаулы азгын шайтаннар – барсы да аның кул астында була. Шулкадәр хакимлеккә ия булуына карамастан, Сөләйман галәйһис-сәләәм: «Мин бер фәкыйрь! Фәкыйрьгә фәкыйрьләр янында булу килешә!» – дип, үксезләр һәм ятимнәр янында йөри.

Түбәндәге бәетендә Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ фәкыйрьләр һәм кайгы-хәсрәтле бәндәләр белән бер дулкында, юлдаш булуның рухи әҗерен бик күркәм аңлата: «Фәкыйрь һәм мохтаҗлыкка чумган күңелләр төтен тулы йортка охшаган. Син аларның кайгы-борчуларын тыңлап, аларга ярдәм кулы сузу нияте белән ул төтенле йортта бер тәрәзә ачып җибәр дә төтене таралып китсен, ә синең йөрәгең пакьләнеп, рухың йомшарсың, нәфисләнсен…»

Мондый халәт инфак (Аллаһ юлында сарыф кылу) аша иң матур чагылыш таба. Инфак бер үк вакытта мал-байлык өчен шөкер итү, рәхмәт белдерү дә булып тора. Шөкернең нигъмәтне арттырачагы турында Аллаһ Тәгалә вәгъдә бирә:

لَئِنْ شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ

**«…Әгәр шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә (нигъмәтләрне) арттырачакмын...»** («Ибраһим», 7).

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә инфак кылуны бик ярата. Бер хәдис-шәрифендә Ул: *«И, адәм баласы! Инфак кыл ки, сиңа да инфак кылынсын...»* – дип әйтә (Бохари, «Тәфсир», 11/2).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез юмартлыкның һәр мөселман өчен асыл холык сыйфатына әйләнүен тели. Аның мондый сүзләре тапшырыла: *«Ике кешегә генә көнләшергә була. Беренчесе – Аллаһ аңа мал-мөлкәт биреп, шуны хак юлда сарыф итәргә мөмкинлек тудырган зат; икенчесе исә – Аллаһ аңа гыйлем биреп, шуның белән гамәл кылучы һәм шуларны башкаларга өйрәтүче (ягъни гыйлемне инфак кылучы) зат»* (Бохари, «Гыйлем», 15; Мөслим, «Мүсафирин», 266–268).

Коръәни-Кәримдә болай диелә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ أَنْتُمُ الْفُقَرَاءُ إِلَى اللَّهِ وَاللَّهُ هُوَ الْغَنِيُّ الْحَمِيدُ

**«И, кешеләр! Сез (һәркайсыгыз) Аллаһка мохтаҗсыз. Аллаһ исә Бай, (Ул гына) Мактауга лаеклы!»** («Фатыйр», 15).

Аяти кәримәдән дә аңлашылганча, мал-мөлкәт, чынлыкта, кешеләрнеке дә, җәмгыятьнеке дә түгел. Мөлкәт – Аллаһныкы. Бөтен җан ияләре Җәнабел-Хак милкендә яши, Ул биргән нигъмәтләр белән тормыш алып бара, җан асрый. Бәндәләргә исә шул милектән бары билгеле бер вакыт аралыгында чикле файдалану мөмкинлеге генә бирелә.

Шунлыктан мал-мөлкәт һәм дәрәҗә бу тормышта иң зур сынау булып тора. Сөләйман галәйһис-сәләәмнең патшалыгы бер мизгелдә тулысынча тартып алына, бары тәүбә нәтиҗәсендә генә кабат үзенә кайтарыла. Бу уңайдан Хак Тәгаләнең бер дустының менә бу нәсыйхәте шулкадәр гыйбрәтле һәм хикмәтле: «Ризык эзләп түгел, Рәззакны эзләп йөр!»

Бервакыт кырмыскалар башлыгының Сөләйман галәйһис-сәләәм патшалыгы турында кырмыскаларга: «Сөләйманның патшалыгы шундый зур, шундый куәтле!» – дип әйткәне риваять кылына. Моны ишеткәч, Хәзрәти Сөләйман галәйһис-сәләәм: «Минем патшалыгым фани; бер тәүхид кәлимәсе бирә торган патшалык исә бакый һәм мәңгелек!..» – дип җавап бирә, чөнки ул чынлыкта мал-мөлкәт һәм хакимлекнең Аллаһныкы икәнен белә.

Аяти кәримәләрдә әйтелә:

مَنْ كَانَ يُرِيدُ الْعِزَّةَ فَلِلَّهِ الْعِزَّةُ جَمِيعًا

**«Кем дә кем бөеклек (һәм дан) теләсә, (белсен ки,) бөеклек (һәм дан) тулысынча Аллаһныкы гына...»** («Фатыйр», 10).

إِنْ كُلُّ مَنْ فِي السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ إِلَّا آتِي الرَّحْمٰنِ عَبْدًا

**«Күкләрдә һәм җирдә булганнарның һәрберсе Рахманга кол буларак кына киләчәк»** («Мәрьям», 93).

وَلِلَّهِ مُلْكُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاللَّهُ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

**«Күкләрнең һәм җирнең милке (һәм хакимлеге) – Аллаһныкы гына. Аллаһ – һәрнәрсәгә Кодрәтле»** («Әли Гыймран», 189).

قُلِ اللَّهُمَّ مَالِكَ الْمُلْكِ تُؤْتِي الْمُلْكَ مَنْ تَشَاءُ وَتَنْزِعُ الْمُلْكَ مِمَّنْ تَشَاءُ وَتُعِزُّ مَنْ
تَشَاءُ وَتُذِلُّ مَنْ تَشَاءُ بِيَدِكَ الْخَيْرُ إِنَّكَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

**«(Әй, Рәсүлем!) Әйт: “И, падишаһлыкның хуҗасы – Аллаһ! Син хакимлекне (һәм мөлкәтне) теләгәнеңә бирәсең, теләгәнеңнән тартып аласың; теләгәнеңне олылыйсың, теләгәнеңне хур итәсең. Бөтен яхшылык – Синең генә хакимлегеңдә. Һичшиксез, Син – һәрнәрсәгә Кодрәтле”»** («Әли Гыймран», 26).

تُولِجُ اللَّيْلَ فِي النَّهَارِ وَتُولِجُ النَّهَارَ فِي اللَّيْلِ وَتُخْرِجُ الْحَيَّ مِنَ الْمَيِّتِ
وَتُخْرِجُ الْمَيِّتَ مِنَ الْحَيِّ وَتَرْزُقُ مَنْ تَشَاءُ بِغَيْرِ حِسَابٍ

**«Син төнне көнгә кертәсең, көнне төнгә кертәсең; үледән терене чыгарасың, тередән үлене чыгарасың. Теләгәнеңне Син хисапсыз ризыкландырасың»** («Әли Гыймран», 27).

Әлеге аяти кәримәләр бәндәләр өчен дөньяның чын байлыгы Аллаһны зикер кылудан, Аны онытмаудан, Аның мәхлукларына хезмәт итүдән һәм Аның ризалыгы өчен инфак кылудан гыйбарәт икәнен күрсәтә.

Коръәни-Кәримдә 200дән артык урында искә алынган инфак – малны һәм җанны Аллаһка багышлау дигән сүз. Ягъни Раббыбыз насыйп иткән нигъмәтләрне янә Аңа багышлап сарыф итүне белдерә. Шуңа күрә мөселман да мал-мөлкәтен дә, җанын да Аллаһка багышлаган зат була.

Иманның тәүге җимеше – мәрхәмәт. Аннан ерак күңел җан иясе, тере зат санала алмас. Һәр хәерле эшнең башы булган «бисмилла» һәм «Фатиха» Аллаһның мәрхәмәтен белдергән «Рахман» һәм «Рәхим» исемнәре белән башлана. Пәйгамбәрләр һәм вәлиләрнең тормышлары да шәфкать һәм мәрхәмәтнең иң югары үрнәкләреннән гыйбарәт гайре табигый күренешләр белән тулы.

Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Мәрхәмәт кылучыларга Җәнабел-Хак мәрхәмәт күрсәтер. Сез җирдәгеләргә мәрхәмәт кылыгыз, күктәгеләр дә сезгә мәрхәмәтле булсын...»* – дип (Тирмизи, «Бирр», 16; Әбу Давыт, «Әдәб», 58), мөэминнәрне бөтен мәхлукларне колачлаган мәрхәмәткә өнди.

Мәрхәмәтлелек Аллаһ колының бер вазифасын тәшкил иткән инфак кылуда иң камил чагылыш таба. Туганлык хисләре зәгыйфьләнгән, иҗтимагый тынычлык һәм иминлек югалган, ачу-нәфрәт һәм дошманлык арткан җәмгыятебездә инфак юлында гомуми мобилизациягә ихтыяҗ бар. Шуны онытмаска кирәк: авырту-сызланулы һәм мохтаҗ кешеләр урынында без дә булырга мөмкин идек. Шуңа күрә безнең инфак кылуыбыз Раббыбыз каршында шөкер кылу бурычыбыз булып тора.

Җәнабел-Хак тәкъва бәндәләрнең сыйфатларын санаганда:

وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنْفِقُونَ

**«...Без ризык итеп биргән нәрсәләрдән (Аллаһ юлында) сарыф итәләр»**, – дип әйтә («әл-Бәкара», 3).

Аллаһ ризалыгы өчен бирүнең гомуми атамасы булган сәдака һәм инфакның төрләре күп. Сәдака һәм инфак булганның артыгын бирүдән башлана. Һич малы-акчасы булмаган бәндә өчен исә хәтта ярты хөрмә дә күркәм сәдака санала. Сәдака биргәндәге ихласлыкка нисбәтле рәвештә бәндәне җәһәннәм утыннан саклар.

Шәфкатьлелек, мәрхәмәтлелекнең һәм боларның иң табигый нәтиҗәсе булган инфакның һәр мөселман өчен асыл холык сыйфатына әйләнүен теләгән Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез, бу яктан караганда. һәр мөэминне бай дип саный, чөнки Ул үзенең хәдис-шәрифләрендә мөэминнәрнең хәерлегә өндәп, яманнан тыю, тәкбир әйтү, Аллаһның берлеген тану, кыерсытылганнарга ярдәм итү, кайгы килгәннәрне юату, мохтаҗларның күңелен күрү, юллардагы комачаулаган нәрсәләрне алып ташлау, авыруның хәлен белү һәм хәтта урынлы елмаю кебек һәртөрле изге гамәле бер сәдака хөкемендә каралуын белдергән. Шунлыктан чын байлык күңелдәге канәгатьлек белән бәйле. Һәркем үзенең канәгатьләнгәнлек дәрәҗәсенә карата бай. Күңеле бай бәндәләрнең хәтта бер елмаюы да сәдака дип саналыр, чөнки бай күңелленең елмаюы андагы мәхәббәт, тынычлык һәм эчке яктылыкны әйләнә-тирәдәгеләргә дә тарата. Чыннан да, нинди күркәм инфак була ул! Ә күңеле ярлыларны исә, киресенчә, бернәрсә дә баета алмый. Бу сүзләрне хәдис-шәриф тә раслый: *«Чын байлык мал күплеге түгел, күңел туклыгы белән»* (Бохари, «Рикак», 15; Мөслим, «Зәкят», 130).

Чын мөэминнәр, дигәндә, күңел байлыгы кебек илаһи нигъмәткә ия булып, инфак кылучылар күздә тотыла. Һәр мөэмин ия булырга бурычлы сыйфатлар – башкалар турында кайгыртучанлык һәм сизгер күңеллелек нәкъ менә инфакта камил чагылыш таба.

Ярмүк явында шәһид киткән Харис ибне Хишам, Икримә ибне Әби Җәһл, Ийаш ибне Әби Рәбига радыйаллаһу ганһүмнәрнең гомере никадәр гыйбрәтле! Соңгы сулышларында сусызлыктан үпкәләре кипкән килеш уттай кайнар комнарда кызганда, бу ислам каһарманнарының һәркайсы үзенә бирелгән бер чынаяк суны башкасына суза, нәтиҗәдә, үлем килгәнче, һичберсенә су биреп өлгерә алмыйлар һәм алар барысы да, бер йотым су эчә алмыйча, шәһидлек ширбәтен татый. Бер чынаяк су уртада утырып кала (Хаким, «Мүстәдрәк», III, 270). Бу каһарманнарның гамәле инфакның иң югары дәрәҗәсе – «исар» үрнәге булып тора. Ягъни мөэмин кардәшеңнең ихтыяҗын үз ихтыяҗыңнан өстен куя белү фазыйләте турында сүз бара.

Җәнабел-Хак болай ди:

الَّذِينَ يُنْفِقُونَ فِي السَّرَّاءِ وَالضَّرَّاءِ وَالْكَاظِمِينَ الْغَيْظَ وَالْعَافِينَ عَنِ النَّاسِ وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُحْسِنِينَ

**«Алар (тәкъвалык ияләре) муллыкта да, тарлыкта да (Аллаһ өчен) сарыф итәләр, ачуларын тыялар һәм кешеләрне гафу итәләр. Аллаһ (үз-үзен шул рәвешле тоткан) игелек кылучыларны сөя»** («Әли Гыймран», 134).

Риваятькә күрә, Җәгъфәри Садыйк Хәзрәтләренең көндәлек хезмәтләрен башкара торган бер колы була. Бервакыт кол Җәгъфәри Садыйкка шулпа салып алып килә һәм касәне ялгыш хуҗасы өстенә түгеп җибәрә. Өс-башы ашка буялган Җәгъфәр Хәзрәтләре ачу белән колының йөзенә карый. Шуннан соң кол: «Әфәндем! Коръәндә «ачуларын тыючылар» мактап телгә алына!» – дип бу хакта аяти кәримәне укый. Җәгъфәри Садыйк Хәзрәтләре: «Ачуымны җиңдем!» – ди. Бу юлы кол: «Коръәндәге шул ук аятьтә “кешеләрне гафу итүчеләр” дә мактала», – ди һәм аятьнең бу хактагы өлешен укып бирә. Җәгъфәр Хәзрәтләре: «Менә сине гафу иттем!..» – ди. Шуннан соң кол: «Коръәндә шул ук аятьнең дәвамында «Аллаһ ихсанлык һәм игелек кылучыларны сөя», диелә!» – дип, аятьнең соңгы кисәген дә укый. Моңа җавап итеп Җәгъфәри Садыйк Хәзрәтләре: «Бар, кит, син инде ирекле; Аллаһ ризалыгы өчен сине азат итәм!..» – дип белдерә. Югарыда бәян кылынганнар – өммәткә үрнәк булырлык никадәр күркәм инфак күренешләре.

Аллаһ Рәсүле белдергәнчә, сусызлыктан хәлсезләнгән эткә су эчергән бер гөнаһлы хатын, бары менә шушы мәрхәмәтле гамәле хөрмәтенә меңнәрчә гөнаһының гафу ителүенә ирешү мөмкинлеге белән бүләкләнеп, җәннәткә лаек була. Моның киресе исә, песиенә мәрхәмәтсезлек күрсәтеп, аның ачлыгына һич игътибар бирмәгән бер хатын җәһәннәм газабына дучар кылына.[154]

Бу мисалларның барысы да күңел дөньябызга бер юнәлеш бирү мәсьәләсендә шулкадәр гыйбрәтле. Мөэмин караңгы төндәге тулы ай кебек нурлы, башкаларны кайгыртучан, сизгер, кече күңелле, мәрхәмәтле, шәфкатьле һәм юмарт булырга тиеш.

Коръәни-Кәримдә Җәнабел-Хак үзенә якын булу мөмкинлеге өчен безгә сөйгән нәрсәләребезне Аллаһ юлында сарыф итүебез тиешлеген белдерә:

لَنْ تَنَالُوا الْبِرَّ حَتّٰى تُنْفِقُوا مِمَّا تُحِبُّونَ وَمَا تُنْفِقُوا مِنْ شَيْءٍ فَإِنَّ اللّٰهَ بِهِ عَلِيمٌ

**«Үзегез ярата торган нәрсәләрдән (Аллаһ юлында) сарыф итми торып, сез изгелеккә (хәерленең иң югары ноктасына) ирешә алмаячаксыз. Нәрсәне сарыф итсәгез дә, һичшиксез, Аллаһ – аны белүче»** («Әли Гыймран», 92).

Аяти кәримәдә кулланылган «бирр» сүзе «хәерле нәрсәнең иң камил ноктасы, Аллаһның рәхмәте, Аның ризалыгы һәм җәннәте» дигән мәгънәләрдә тәфсир ителә. Шул ук вакытта Җәнабел-Хак аны башка бер аяти кәримәдә түбәндәгечә ачыклап китә:

154. Бохари, «Әнбия», 54; Мөслим, «Сәлам», 151–152.

لَيْسَ الْبِرَّ أَنْ تُوَلُّوا وُجُوهَكُمْ قِبَلَ الْمَشْرِقِ وَالْمَغْرِبِ وَلَكِنَّ الْبِرَّ مَنْ آمَنَ بِاللّٰهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ وَالْمَلَائِكَةِ وَالْكِتَابِ وَالنَّبِيِّينَ وَآتَى الْمَالَ عَلَى حُبِّهِ ذَوِي الْقُرْبٰى وَالْيَتَامٰى وَالْمَسَاكِينَ وَابْنَ السَّبِيلِ وَالسَّائِلِينَ وَفِي الرِّقَابِ وَأَقَامَ الصَّلَاةَ وَآتَى الزَّكَاةَ وَالْمُوفُونَ بِعَهْدِهِمْ إِذَا عَاهَدُوا وَالصَّابِرِينَ فِي الْبَأْسَاءِ وَالضَّرَّاءِ وَحِينَ الْبَأْسِ أُولَئِكَ الَّذِينَ صَدَقُوا وَأُولَئِكَ هُمُ الْمُتَّقُونَ

**«Игелек (бирр) – йөзләрегезне көнчыгыш яки көнбатыш тарафына юнәлдерүегез түгел. Ләкин чын игелек (ияләре) – Аллаһка, Ахирәт көненә, фәрештәләргә, Китапка һәм пәйгамбәрләргә иман китергән; кадерле булганыннан (үзе өчен никадәр кыйммәтле булса да, Аллаһның ризалыгын күздә тотып) туганнарына, ятимнәргә, мескеннәргә, юлда калганнарга, теләнчеләргә һәм коллар азат итүгә мал сарыф иткән; намазны (дикъкатьле һәм даими) укыган, зәкят биргән, вәгъдәләшкән чакта сүзләрендә торган, кыенлыкта, авырлыкта һәм афәтләр вакытында сабыр иткәннәр ул. Әнә шулар (шул сыйфатларга ия булучылар) – тугрылыклы кешеләр һәм әнә шулар тәкъвалык ияләре»** («әл-Бәкара», 177).

Күренгәнчә. «бирр» сүзенә аңлатма биргән әлеге аяти кәримә мөэминдә булырга тиешле барлык өстен сыйфатларны үзендә туплаган. Моңа ишарәләп, Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез: *«Кем дә кем бу аять белән гамәл кылса, иманын камил дәрәҗәгә ирештерер»*, – дип әйткән (Нәсәфи, «Мәдарикүт-Тәнзил», I, 249).

Матди һәм рухи инфакның билгеле бер иҗтимагый институт рәвешенә килгән формасын вакфлар тәшкил итә. Вакф – Аллаһ тарафыннан яралтылган һәрнәрсәгә карата мөселманда булырга тиешле кайгыртучанлык бурычының бер гәүдәләнеше ул. Чөнки вакфлар Яралтучыдан бигрәк яралтканнарга карата мәрхәмәт, шәфкать һәм мәхәббәтнең бер оешма рәвешен алган иҗтимагый институт санала. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү кешене, дөньяны, әйберләрне әманәт итеп кабул итәргә куша. Бу дөньяда һәрнәрсә кешегә әманәт итеп бирелгән. Бала, мал-мөлкәт, саулык – боларның барысын да әманәт төшенчәсе берләштерә. Бәндә аларны игътибарлы, кайгыртучан рәвештә сакларга бурычлы. Әманәт хакына тугрылык һәм аны тиешле иясенә тапшыру рәхмәт һәм бәрәкәт нигезен тәшкил итә.

Сөләйман галәйһис-сәләәм белән чыпчык арасындагы югарыда искә алынган атаклы әңгәмә вакф мәсьәләсендә күрсәтелергә тиешле әһәмиятлелек, җитдилеккә игътибар юнәлтү ягыннан да бик гыйбрәтле. Кыскасы, вакф хезмәтендә булучыларның кыйссадан тиешле сабак алулары зарур.

Байлык мәсьәләсендә дөрес максатны билгеләр өчен, *«Кешеләрнең иң хәерлесе – кешеләргә иң күп файдалы булучы»* хәдис-шәрифенең (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», II, 8) серенә төшенү тиеш. Шуны онытмаска кирәк: акча-

ның урыны йөрәк түгел, ә акча янчыгы!.. Бер атаклы шагыйрьнең түбәндәге дүртьюллыгы кешенең дөнья нигъмәтләренә карата ваемсызлыгын бик матур сурәтли:

«Бер мосафирханәдер – бу түбән дөнья,
Мәһабәт сарай да, җимерек йорт та анда,
Һич савыкмас, чарасыз сөюдәмен,
Бер йорт төзеттем мосафирханәдә!..»

Фәкыйрьләрнең һәм үксезләрнең догалары байлар һәм көчлеләр өчен рәхмәт һәм бәрәкәт нигезе, шулай ук иминлек, тынычлык чыганагы икәнен белеп торырга кирәк. Шуннан да хәбәрдар булу зарур: фәкыйрьлек һәм мохтаҗлык хурлык һәм мескенлек түгел ул, бәлки ахирәт тарафы яктылыктан гыйбарәт хикмәт һәм илаһи рәхмәт чагылышыдыр.

Өмәййә ибне Халид радыйаллаһу ганһенең риваятенә күрә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһтан фәкыйрь мөһаҗирләр хөрмәтенә мөселманнарга җиңү һәм ярдәм насыйп итүен сорый (Табәрани, «Мугҗәм әл-Кәбир», I, 292).

Әбү Дәрда радыйаллаһу ганһенең риваятенә күрә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләрен*: «Минем яныма зәгыйфьләрне чакырыгыз, чөнки сез зәгыйфьләрегезнең (догасы һәм бәрәкәте) белән ризыкландырыласыз һәм ярдәм аласыз»*, – дип нәсыйхәтли (Әбу Давыт, «Җиһад», 70; Ибне Ханбәл, V, 198).

Адәм баласы мәхлуклар арасында иң хөрмәтле зат итеп яратылган. Кешеләр арасында көчле-зәгыйфь, сау-авыру, белемле-надан, ярлы-бай кебек үзенчәлекләр нигезендә аермалыклар барлыкка килү, катламнарга бүленү исә җәмгыятьтәге тәртипнең формалашуы һәм иҗтимагый тормышның гармониясен тәэмин итү өчен зарур. Бу катламнарга бүленүдә әһәмиятле урын биләгән байлык һәм фәкыйрьлек капма-каршы ике икътисади халәтне тәшкил итә. Байлык һәм ярлылык кебек төрле мөмкинлекләргә ия булу сыйфатында илаһи тәкъдирнең тирән хикмәтләре яшеренгән. Шуңа күрә бай булу – бөеклеккә, горурлыкка, ярлылык исә хурлыкка, түбәнлеккә сәбәп түгел. Һәр ике халәт тә имтихан максаты белән башкарылган илаһи бүленеш, язмышның бер хикмәтле күренеше булып тора. Аллаһ Тәгалә әйтә:

أَهُمْ يَقْسِمُونَ رَحْمَتَ رَبِّكَ نَحْنُ قَسَمْنَا بَيْنَهُمْ مَعِيشَتَهُمْ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَرَفَعْنَا بَعْضَهُمْ
فَوْقَ بَعْضٍ دَرَجَاتٍ لِيَتَّخِذَ بَعْضُهُمْ بَعْضًا سُخْرِيًّا وَرَحْمَتُ رَبِّكَ خَيْرٌ مِمَّا يَجْمَعُونَ

**«...Дөнья тормышында (кешеләрнең) ризыкларын араларында Без бүлгәләдек һәм берәүләре икенчеләрен хезмәтче итеп алсыннар, дип, Без аларның кайберләрен кайберләреннән дәрәҗәләрдә күтәрдек. Раббыңның рәхмәте исә аларның җыйган нәрсәләреннән яхшырак»** («әз-Зүхруф», 32).

Бай кешеләрнең мал-мөлкәткә табынуы нәтиҗәсендә барлыкка килүе ихтимал бозыклыкларга киртә кую, мохтаҗларның күңелендә байларга карата ачу-нәфрәт һәм көнчелек кебек тискәре омтылышлар бөреләнүен туктату, иҗтимагый тормыш иминлеген саклау һәм кешеләрне бер-берсенә мәхәббәт белән якынайту, бәйләү кебек хикмәтләргә ия зәкят гамәле исламда бай мөэминнәр өчен фарыз кылынган. Ислам җәмгыятендә бай белән ярлы арасындагы баланс һәм мәхәббәтне тәэмин итү мәсьәләсендә зәкят түләү һәм сәдака бирү кебек гыйбадәтнең бик мөһим урыны бар.

Бай кеше малны ничек табып кая сарыф итүе мәсьәләсендә, ягъни хәләл яки хәрәм юл белән алынган кереме, зәкят, сәдака, хәерле һәм күркәм эш-гамәлләре турында Аллаһ каршында хисап тотачак. Мөлкәтенең билгеле бер өлешен фәкыйрьләргә бирү бурычы аның өчен байлык белән бәйле бик зур сынауны тәшкил итә. Ләкин башка сынаулар белән бергә бу имтиханны да уңышлы тапшырган очракта, бәндә Аллаһ ризалыгына һәм җәннәт нигъмәтләренә лаек була. Ярлы бәндә дә фәкыйрьлек белән бәйле сабырсызлык, зарлану, бүтән кешеләр ярдәменә салынып, алар өчен артык йөк булу, мохтаҗлыкка катнашы юк теләк-омтылышлар, ачу, көнчелек, итагатьсезлек кебек мәсьәләләр белән беррәттән әхлагын һәм гыйффәтлелеген саклау-сакламау турында да хисап тотачак, әгәр бу хисап нәтиҗәсеннән Аллаһ разый булса, бу бәндәнең дөньядагы җәфалары мәңгелек ахирәт бәхетенә әйләнәчәк.

Шөкер итеп яшәүче юмарт байлар белән сабыр-түзем фәкыйрьләр кеше буларак хөрмәт ителүдә һәм илаһи ризалыкка ирешүдә тиңдәшләр. Исламда тәкәббер, саран байлар һәм үз хәленә сабыр итә белмәгән, ризасызлык белдереп, илаһи тәкъдиргә каршы чыккан фәкыйрьләр тәнкыйтьләнә. Шунлыктан байлык та, ярлылык та зур сынау булып тора. Әнә шуңа күрә Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм догаларында*: «Йә, Раббы! Фәкыйрьлек һәм байлык афәтләреннән Сиңа сыгынам»*, – дип ялвара торган булган (Бохари, «Дәгъват», 45). Бу очракта канәгатьлек, буйсынучанлык һәм итагатьлелек кемдә өстен чыкса, шул чын бай булыр...

Кыскасы, кеше табигате белән дөньялыкка тартыла. Дөнья нигъмәтләре нәфесне үзенә җәлеп итә. Дөнья ләззәтләренә алданучылар туя белми. Мал күбәйгән саен, кеше ачкүзләнә бара, тагын да комсызлана. Күзен акчага, байлыкка хирыслык каплап алган бәндәдә мәрхәмәтлелек һәм шәфкать хисе азая. Аллаһ юлында сарыф итү аңа бик кыен бирелә. Мондый кешенең тәне сызланулы, рухы авыру була. Нәфесе аны: «Син тагын да баерак бул, киләчәктә шул рәвешле күбрәк хәерле эшләр эшли алырсың!» – дип котыртып тора. Ләкин хәдистә: *«Иртәгә эшләрмен, диючеләр һәлак булды»*, – диелгәнне онытмаска кирәк, чөнки иртәгәсе көннең барысы да билгесез, ни буласын белмибез.

Җәнабел-Хак аяти кәримәдә, үлем мизгелендә йокыдан уянган кебек үз акылына кайткан бәндәнең мәңгелек үкенечкә батып, болай дигәнен белдерә:

رَبِّ لَوْلَا أَخَّرْتَنِي إِلَىٰ أَجَلٍ قَرِيبٍ فَأَصَّدَّقَ وَأَكُنْ مِنَ الصَّالِحِينَ

**«...Раббым! Мине(м үлемемне) якын бервакытка кадәр кичектерсәң, күп итеп сәдака бирер идем һәм изге кешеләрдән булыр идем!»** («әл-Мунафикун», 10).

Тик бу вакытта инде эш узган булганга күрә, шул ук аяти кәримәдә Аллаһ Тәгалә бәндәгә, мондый сүзләрне әйткәнче, аңа бирелгән ризыктан сәдака бирергә (инфак кылырга) куша. Югыйсә бәндә үкенеч диңгезенә чумачак, бу хакта аяти кәримәләрдә никадәр гыйбрәтле итеп белдереп куела:

كَأَنَّهُمْ يَوْمَ يَرَوْنَهَا لَمْ يَلْبَثُوا إِلَّا عَشِيَّةً أَوْ ضُحَاهَا

**«Алар аны күрәсе (кыямәт) көнне үзләрен бер төштән соң (ахшам вакыты) яки төшкә кадәр генә торган дип санарлар»** («ән-Нәзигать», 46).

ثُمَّ إِنَّكُمْ يَوْمَ الْقِيَامَةِ تُبْعَثُونَ

**«Аларның (каберләреннән) чыккан көнендә алар турында берни дә Аллаһтан яшерен калмаячак. “Бүген хакимлек кемнеке?” “(Әлбәттә) Бердәнбер һәм Юк итүче булган Аллаһныкы!”»** («әл-Гафир», 16).

وَلَوْ تَرَىٰ إِذِ الْمُجْرِمُونَ نَاكِسُو رُءُوسِهِمْ عِنْدَ رَبِّهِمْ رَبَّنَا
أَبْصَرْنَا وَسَمِعْنَا فَارْجِعْنَا نَعْمَلْ صَالِحًا إِنَّا مُوقِنُونَ

**«Әгәр дә гөнаһлыларның Раббылары хозурында башларын игәннәрен (һәм болай дигәннәрен) күрсәң иде: «И, Раббыбыз! Күрдек һәм ишеттек. Син безне (дөньяга кире) кайтар да, изге бер гамәл кылыйк, чөнки, һичшиксез, без – шиксез инанучылар»** («әс-Сәҗдә», 12).

### Инфак әдәбе

Сәдака биргәндә, инфак кылганда әдәп бик мөһим. Беренче чиратта, бирүче алучыга рәхмәт хисе тоярга тиеш, чөнки аның Җәнабел-Хакка шөкер кылу бурычы булган матди гыйбадәтенең үтәлүенә булышып, бирүчене әҗер-савапка лаек кыла. Бирелгән сәдакаләр – бер үк вакытта бирүче зат өчен төрле авыру-казалардан калкан, үзенә күрә яшеннән саклаучы да. Аяти кәримәдә бу гыйбадәтнең әһәмиятен белдерү өчен, күчерелмә мәгънәдә: **«Сәдакаларны Аллаһ алыр»**, – дип әйтелә («әт-Тәүбә», 104).

Инфак кылганда үтәлергә тиешле әдәп турында Коръәни-Кәрим болай ди:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تُبْطِلُوا صَدَقَاتِكُمْ بِالْمَنِّ وَالْأَذَىٰ كَالَّذِي يُنْفِقُ مَالَهُ رِئَاءَ النَّاسِ وَلَا يُؤْمِنُ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ

**«И, иман китерүчеләр! Аллаһка һәм Соңгы көнгә ышанмаган, кешегә күрсәтер өчен генә малын сарыф иткәннәр кебек, битәрләү һәм кимсетүләрегез белән сәдакаларыгызны юкка чыгармагыз…»** («әл-Бәкара», 264).

Бу аятьләрдә изге гамәлләргә өндәү белән бергә, игелекле эшләр кылганда үтәлергә тиешле әдәп-әхлак мәсьәләсе гаять ачык рәвештә күтәрелә. Аятькә күрә, кешенең күңелен кырып, фәкыйрь бәндәне кимсетеп, түбәнсетеп, бу хакта гел искә төшереп башкарыла торган изгелекнең Аллаһ каршында һичбер кыйммәте юк. Чынлыкта, мондый изге гамәлләр бәндәне газапка дучар итә торган гөнаһлар санала, чөнки Аллаһ йөрәктәгеләргә карый. Мәүләна Хәзрәтләре: «Син мал-мөлкәтеңне күркәм рәвештә Аллаһ юлында сарыф ит тә, бер күңелне күр! Ул күңелнең догасы кабердә, шул кап-кара төндә сиңа яктылык бирсен, нур булсын!..» – дип яза.

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ хикмәт тулы бәетләрендә Җәнабел-Хакка шөкер итү вазифасының үтәлешенә бер нигез булганга күрә, ярлыларның, мохтаҗларның юмарт затлар өчен бер нигъмәт икәнлеген, юмартлык сыйфатының бары шундый мохтаҗлар ярдәмендә генә билгеле бер чагылыш табуын, шунлыктан да аларның күңелен рәнҗетмәскә кирәклеген түбәндәгечә бәян кыла:

«Ярлы кеше – юмартларның көзгесе ул. Көзгегә карата күңелне кырырлык сүзләр әйтеп, аны парландырма, тоныклатма! (Ягъни фәкыйрьнең күңеленә нәзакәтле, игътибарлы мөнәсәбәттә бул, чөнки күңелне Аллаһ күзәтеп тора)».

«Аллаһның юмартлык сыйфаты фәкыйрьләр аша чагылыш таба. Ул фәкыйрьләр бары юмартлык ияләренә генә мөрәҗәгать итә, хәсрәт-борчуларын шуларга сөйлиләр. Шул рәвешле кешелекле байлар өчен алар бәхет юлларын хәзерли. Байларның хәер-сәдака белән ярлыларның күңеленә үтеп керүдәге башка бер бәрәкәт җәфа чиккән, хәсрәтле күңелләрдә үзләренә карата сөю һәм мәрхәмәт орлыклары бөреләнүдән гыйбарәт».

«Бу очракта ярлылар Хак Тәгаләнең юмартлык көзгесе булып тора. Байлар үз юмартлыкларын шунда күзәтә алыр. Хак Тәгаләне таныган изге байлар, мал-мөлкәтләренең бер әманәт икәнлеген аңлап, Аллаһ каршында үз-үзләрен, нәфесләрен таныйлар һәм илаһи юмартлыкның чагылышына әвереләләр. Хак Тәгаләнең юмартлыгыннан бер өлеш алып, юмартлыкта Аңа якынаялар».

«Азмы яки күпме байлыгына күңелен әсир төшермичә, малга хирыслыкны йөрәктән читтә йөрткәннәрдән кала башкалар исә бәдбәхет һәм ахирәттәге фәкыйрьләр була. Бу төр кешеләр хакыйкать ишегенә якын килмәс. Аларның

байлыклары да чагыштырмача гына, хакыйкать ишегенең тышкы ягындагы бизәк-рәсемнәрдән генә гыйбарәт».

«Болар – күңелләре Аллаһтан ерагайган чын мескеннәр һәм рухи фәкыйрь затлар. Тышкы, күзгә күренә торган мал-мөлкәтләре исә бәдбәхетлекләренең җансыз бизәге, томанлы, тонык рәсеме кебек. Болар – хакыйкатьне белмәүче, җансыз бәндәләр, син андыйлар белән якын булма! Сак бул, эт рәсеменә сөяк ташлама!..».

«Мондый кешеләр үз мәнфәгатьләренә әсир төшә. Алар хакыйкатькә сусау хакында һичнәрсә белмиләр».

«Игътибарлы бул; бу мәетләр алдына ризык салынган тәлинкә куйма! Ягъни илтифат күрсәтеп, аларга якынайма! Мондый байлар мәхшәр көненең иң чиркангыч теләнчеләре булачак!».

«Андыйлар мәгънә түгел, ә икмәк дәрвишләре. Алар туфрак балыгына охшар, тышкы карашка балыкка охшасалар да, диңгездән куркып качарлар».

«Алар үзләренең түбәнлекләрен, җирәнгечлекләрен бәхет, дип уйлыйлар, үзләренә күрә тәмле ризыклар ашыйлар, татлы ширбәтләр эчәләр. Чынлыкта исә алар илаһи ризык кисәгеннән мәхрүм ителгән».

«И, мондый хәсрәткә төшәргә теләмәүче зат! Син мәхлукларны юмартлыгың белән кочаклап ал, хакыйкатькә ирешүчеләрдән булырсың!..».

Юмартлык көзгесе булган фәкыйрьләргә сәдака биргәндә үтәлергә тиешле иң күркәм әдәп кагыйдәсе – «уң кулын биргәнне хәтта сул кулың да белмәсен» рәвешендә халкыбызның мәкаль-әйтеменә әйләнгән. Бер хәдис-шәрифкә күрә, шушы кагыйдә кушканча сәдака бирүчеләр гареш күләгәсендә торачак бәхетле затлар булачак.[155] Бу таләп үтәлә алсын өчен, ата-бабаларыбыз хисапсыз вакфлар оештырган. Бу вакфлар аша бирелә торган сәдакалар исеме билгесез шәхесләрдән килгәнгә күрә, бирүче риялыктан котыла. Алучы исә бирүченең кем икәнен белмичә генә аңа дога кыла. Фатих Мәхмәд солтанның вакфка мал-мөлкәт тапшыруы инфак кылуның никадәр күркәм үрнәге булып тора:

«Мин – Аллаһның гаҗиз колы, Истанбулны яулаган Фатих Мәхмәд солтан – маңгай тирем белән эшләп булдырган 136 кибетемне түбәндәге шартлар кысасында вакфка тапшырам: “...Көллиямдә төзеткән ашханәмдә шәһидләрнең хатыннары, ятимнәре һәм Истанбулның фәкыйрьләре өчен ризык әзерләнсен! Ә ашарга яки ризык алырга килә алмаган гарип-горабага ашамлыклары, караңгы төшкәч, ябык савытлар эчендә, чит күзләр күрмәслек итеп илтеп бирелсен!..».

Вакф кылу язмасыннан күренгәнчә, Фатих Мәхмәд солтан җәмгыятьнең яклауга мохтаҗ затларына карата иң нәзакәтле мөнәсәбәтне күздә тоткан әдәп

155. Карагыз: Бохари, «Азан», 36.

кагыйдәләрен керткән. Падишаһ мондый әдәп үрнәге күрсәткән җәмгыятьнең әгъзалары да зәкятләрен конверт эчендә мәчетләрдәге зәкят ташларына куя торган була, мохтаҗлар исә хәер-сәдакалардан үз ихтыяҗларына кирәк кадәрен, бирүчене күрмичә-белмичә, шуннан ала.

Икенче яктан караганда, авыр хәлдә калулары турында гыйффәтлелеге, оялчанлыгы аркасында әйтә алмаучыларга сәдака бирү дә бик мөһим. Җәнабел-Хак болай ди:

لِلْفُقَرَاءِ الَّذِينَ أُحْصِرُوا فِي سَبِيلِ اللهِ لَا يَسْتَطِيعُونَ ضَرْبًا فِي الْأَرْضِ يَحْسَبُهُمُ الْجَاهِلُ أَغْنِيَاءَ مِنَ التَّعَفُّفِ تَعْرِفُهُمْ بِسِيمَاهُمْ لَا يَسْأَلُونَ النَّاسَ إِلْحَافًا وَمَا تُنْفِقُوا مِنْ خَيْرٍ فَإِنَّ اللهَ بِهِ عَلِيمٌ

**«(Безнең хәерле эшләребез) Аллаһ юлында тоткарланган, җирдә йөри алмаган фәкыйрьләргә. Тыйнаклыклары аркасында, белмәгән кеше аларны бай дип санар. Син аларны йөз-кыяфәтләреннән танырсың. Алар йөдәтә-йөдәтә кешеләрдән соранмыйлар. Хәердән нәрсә сарыф итсәгез дә, һичшиксез, Аллаһ – аны Белүче»** («әл-Бәкара», 273).

الَّذِينَ يُنْفِقُونَ أَمْوَالَهُمْ بِاللَّيْلِ وَالنَّهَارِ سِرًّا وَعَلَانِيَةً فَلَهُمْ أَجْرُهُمْ عِنْدَ رَبِّهِمْ وَلَا خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلَا هُمْ يَحْزَنُونَ

**«Төнлә һәм көндез, яшерен һәм ачыктан-ачык малларын сарыф иткән кешеләргә – Раббылары катында әҗерләре. Аларга бернинди дә курку булмас, алар хәсрәт тә чикмәс»** («әл-Бәкара», 274).

Диннең төп максаты, Аллаһның берлеген таныганнан соң, күркәм холыклы, сизгер күңелле кеше тәрбияләп, шул нигездә имин, тыныч җәмгыять мохите булдырудан гыйбарәт. Мондый камиллек исә күңелдә формалашкан шәфкать һәм мәрхәмәт хисе белән, шуларның иң күркәм чагылышы булган зәкят һәм инфак кылу аша гына чынга аша ала. Бер мөэмин бәндә йөрәге Раббының бөтен мәхлукларын шәфкать һәм мәрхәмәт белән колачлап алырга, сыендырырга тиеш.

Раббыбыз бар иткән байлыкта, Аның мал-мөлкәтендә яшибез. Аның нигъмәтләре белән тукланабыз. Матди гыйбадәтләргә игътибарсыз мөнәсәбәттә булучылар, кимсетеп караучылар боларның кем малы икәнен, аны кемнән яшерүләре турында уйламыйлар микән әллә?

Сөюнең нәтиҗәсе фидакярлектән гыйбарәт. Сөюче зат сөеклесенә карата мәхәббәт нисбәтендә фидакярлек кылуны бер рәхәтлек һәм бурыч буларак кабул итә. Мондый фидакярлек, гашыйк бәндәнең сөеклесе хакына җан бирүенә кадәр җитә. Аллаһның мәхлукларына карата инфак кылу гашыйкның сөеклесенә карата мәхәббәтенең иң күркәм гәүдәләнеше булып тора, чөнки

зәкят һәм сәдаканың Аллаһ ризалыгы өчен бирелүе аркасында, аларны «Аллаһ ала» рәвешендә гыйбарә барлыкка килгән. Аяти кәримәдә:

أَلَمْ يَعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ هُوَ يَقْبَلُ التَّوْبَةَ عَنْ عِبَادِهِ
وَيَأْخُذُ الصَّدَقَاتِ وَأَنَّ اللَّهَ هُوَ التَّوَّابُ الرَّحِيمُ

**«…Аллаһ колларыннан тәүбәне кабул иткәнен һәм (ихласлык белән, чын күңелдән бирелгән) сәдакаларын (зәкятләрен) алганын (кире бормаганын)... белмиләрме әллә?»** – дип әйтелә («әт-Тәүбә», 104).

И, мал-мөлкәтнең чын хуҗасы булган Аллаһым! Мәрхәмәт, шәфкать һәм синең юлыңда инфак кылуның барлык күренешләре күңел дөньябызның бетмәс-төкәнмәс хәзинәсенә әйләнсен!

Амин!..


Средиземное море
Дамаск
Хайфа
Табарийа
Насира
Палестина
Река Иордан
Бусра
Йафа
Эриха
Амман
Иерусалим
Ашдод
Ашкелон
Вифлеем
Водии мўрчагон
Мертвое море
Содом
Иерусалим
Аравийский полуостров
Саба
Йемен
Мариб



# Хәзрәти
# Гозәер
*галәйһиссәләм*

### *Йөзьеллык үлемнән соң кабат терелтелеп, кыямәт көнендә яңадан торгызылуга үрнәк булган*

# ХӘЗРӘТИ ГОЗӘЕР

### *галәйһис-сәләәм*

Һарун галәйһис-сәләәм нәселеннән чыккан пәйгамбәр. Тәүратны ятлаган сирәк затларның берсе. Яһүдиләрдә «Әзра» исеме белән билгеле.

Хәзрәти Гозәернең пәйгамбәрме-түгелме икәнлеге турында Коръәни-Кәримдә анык мәгълүмат юк. Шулай ук Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: *«Гозәернең пәйгамбәр булганмы-юкмы икәнен белә алмыйм!..»* – дигән (Әбү Давыт, «Сөннәт», 13/4674; Гали әл-Мүттакый, XII, 81/34087).

Коръәни-Кәримдә Аллаһ Тәгалә тарафыннан җаны алынып, йөз елдан соң кабат терелтелгәнлеге генә әйтелә.

Хәзрәти Гозәер яшәгән чорда, азгынлыклары, бозыклыклары арткан Исраил угылларының башына бәла итеп, Аллаһ Тәгалә Бухтүннасрны хөкемдар итә. Бухтүннаср Димәшкъ һәм Иордан төбәкләрен яулап ала. «Әл-Әкъса» мәчетен җимерә, бакча-кырларны юк итә. Яклаучысыз калган кешеләрне ерткычларча үтереп, яшь һәм эшкә ярарлык дип күренгән кешеләрне әсир төшереп, үз янына алып китә. Хәзрәти Гозәер дә шулар арасында була.

Риваятькә күрә, Гозәер галәйһис-сәләәм илле яшендә чакта әсирлектән качып котыла. Бер ишәк белән Иерусалимгә таба юл тота. Иерусалимгә якынайгач, шәһәрнең җимерек биналарын, юк ителгән бакча-кырларын күреп кайгыга чума. Карыны шактый ачыкканга күрә, ишәген бер агачка бәйләп, шунда берникадәр инҗир җыеп ашый. Йөзем сыгып, шуның суын эчә. Аннары бер агач астына килеп утыра. Җимерелгән, тар-мар ителгән калага, череп яткан гәүдәләргә, өеп куелган сөякләргә гыйбрәт белән карап тора. Хак Тәгаләнең кодрәте турында фикерләп, һәрнәрсәнең яңадан ничек терелтеләчәген уйлый-уйлый йокыга тала.

Аллаһ Тәгалә әйтә:

أَوْ كَالَّذِي مَرَّ عَلَىٰ قَرْيَةٍ وَهِيَ خَاوِيَةٌ عَلَىٰ عُرُوشِهَا قَالَ أَنَّىٰ يُحْيِي هَٰذِهِ اللَّهُ بَعْدَ مَوْتِهَا فَأَمَاتَهُ
اللَّهُ مِائَةَ عَامٍ ثُمَّ بَعَثَهُ قَالَ كَمْ لَبِثْتَ قَالَ لَبِثْتُ يَوْمًا أَوْ بَعْضَ يَوْمٍ قَالَ بَلْ لَبِثْتَ مِائَةَ عَامٍ
فَانْظُرْ إِلَىٰ طَعَامِكَ وَشَرَابِكَ لَمْ يَتَسَنَّهْ وَانْظُرْ إِلَىٰ حِمَارِكَ وَلِنَجْعَلَكَ آيَةً لِلنَّاسِ وَانْظُرْ إِلَى
الْعِظَامِ كَيْفَ نُنْشِزُهَا ثُمَّ نَكْسُوهَا لَحْمًا فَلَمَّا تَبَيَّنَ لَهُ قَالَ أَعْلَمُ أَنَّ اللَّهَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

**«Яки нигезенә кадәр җимерелеп беткән авылдан үткән кеше турында (уйла). Ул: "Үлгәненнән соң Аллаһ моны ничек терелтер икән?" – дигән иде. Аллаһ йөз елга аның җанын алды, шуннан терелткән иде. Ул: "Күпме тордың?" – дигәч, ул исә: "Бер көн яки көннең бер өлеше тордым", – дигән иде. Ул: "Түгел, син йөз ел тордың. Ашамлык һәм эчемлекләреңә кара, үзгәрмәгәннәр (бозылмаганнар). Инде ишәгеңә кара. Сине кешеләр өчен бер билге (гыйбрәт) итәргә дип (йөз ел үле килеш тоттык, аннары кабат терелттек). Сөякләрне ничек җыйганыбызны, шуннан соң аларга ит кундырганыбызны кара", – дигән иде. (Итләре черегән, сөякләре кисәк-кисәк аерылган ишәк Аллаһның кодрәте белән кабат терелә.) Аңа күрсәтелгәч (хәлне аңлагач), Ул (Гозәер): "Һичшиксез, Аллаһның һәрнәрсәгә кодрәтле булганын беләм", – диде»** («әл-Бәкара», 259).

Гозәер галәйһис-сәләм йоклаган чакта таң аткан вакыт, ә уянганда әле кояш батмаган була. Ләкин шул арада йөз ел узып китә. Бу вакытта инде Бухтүннаср үлгән, бөтен әсирләр ирек алып, Иерусалимгә кайталар. «Әл-Әкъса» мәчете төзекләндерелгән һәм бөтен кала кабат торгызылган.

Үзе шаһит булып кичергән шушы гаҗәп күренешләрдән соң, Гозәер галәйһис-сәләм ишәгенә атланып, Иерусалим шәһәренә килеп кергәч, бөтен нәрсәнең үзгәргәнен күрә. Кешеләр дә таныш түгел, биналары да ят. Фаразлап булса да, Гозәер галәйһис-сәләм үз мәхәлләсе булырга тиеш урынны эзли. Бер өй каршына туктап, аның ишек төбендә очраткан сукыр һәм гарип хатыннан: «Гозәернең өе кайсы?» – дип сорый.

Теге хатын, хәсрәтләнеп: «Гозәернең өе шушы, тик үзе йөз ел элек югалды. Мин исә аның җариясе булам!» – ди.

Хәзрәти Гозәер: «Мин Гозәер инде!» – дип, үзен таныта да башыннан кичкәннәрне сөйли. Җариясе бик сөенеп, әүвәлге хәленә кайту өчен, дога кылуын сорый. Гозәер галәйһис-сәләм, аңа Җәнабел-Хак биргән нигъмәтләргә шөкер әйтеп, дога кыла. Җария хатынның элекке саулыгы һәм килеш-кыяфәте кайта.

Йокыга талган чакта, Хәзрәти Гозәернең 18 яшьлек улы кала. Хәзер инде ул 118 яшьлек ак сакаллы карт була. Бу картның атасы – Гозәер галәйһис-сәләм исә 50 яшьлек зат кыяфәтендә. Улы атасын таный алмый: «Атамның аркасында ай рәвешендә кара миңе бар иде!» – ди ул. Гозәер галәйһис-сәләмнең аркасын ачып карагач, ай рәвешендәге кара миңне күрәләр. Инде һичкемдә бу кешенең Хәзрәти Гозәер икәнлегенә шик калмый.

Иерусалимне яулап алып, Бәйтүл-Макдисне җимергән чакта, Бухтүннаср барлык Тәүрат нөсхәләрен дә яндырта. Шуңа күрә Гозәер галәйһис-сәләм динне яңадан торгыза.[156]

156. Карагыз: Бурсәви, «Рухул Бәян», II, 512–513, Әркам йайынлары, Истанбул, 2005.

Ибне Габбастан тапшырылган риваятькә күрә, *Аллаһ Тәгалә Исраил угылларының Тәүратны читкә тибәреп, үз теләк-омтылышларына ияргәнен күргәч, Тәүрат салынган сандыкны алардан тартып ала, изге китапның эчтәлеген дә оныттыра. Исраил угыллары моңа бик кайгыра. Аеруча Гозәер галәйһис-сәләәм Аллаһка күп гыйбадәт кыла, Аңа ялварып дога укый. Аллаһтан иңгән бер нур аның йөрәгенә үтеп керә, шуннан соң Тәүрат Гозәер галәйһис-сәләәмнең исенә төшә һәм ул китапны яңадан Исраил угылларына өйрәтә. Соңрак эчендә Тәүрат сакланган сандык та табыла. Исраил угыллары Гозәер галәйһис-сәләәм өйрәткән Тәүратның асыл нөсхәгә туры килгәнен күрә һәм аларның Гозәер галәйһис-сәләәмгә карата мәхәббәте-хөрмәте тагын да ныгый.*

*Мондый искиткеч илаһи күренешләр каршында Бәни Исраил кавеме, соңга таба ялган гакыйдәгә ияреп, Гозәер галәйһис-сәләәмне илаһилаштыра башлыйлар, хәтта аны «Аллаһның улы» дип атауга кадәр барып җитәләр* (Табәри, «Җамигуль-Бәян», X, 143).

Аяти кәримәләрдә болай дип хәбәр ителә:

وَقَالَتِ الْيَهُودُ عُزَيْرٌ ابْنُ اللّٰهِ وَقَالَتِ النَّصَارَى الْمَسِيحُ ابْنُ اللّٰهِ ذَلِكَ قَوْلُهُمْ بِأَفْوَاهِهِمْ
يُضَاهِئُونَ قَوْلَ الَّذِينَ كَفَرُوا مِنْ قَبْلُ قَاتَلَهُمُ اللّٰهُ أَنَّىٰ يُؤْفَكُونَ

**«Яһүдиләр: “Гозәер – Аллаһның улы”, – диде. Насаралар исә: “Мәсих (Гайсә) – Аллаһның улы”, – диде. Аларның бу авызлары белән сөйләгәннәре элекке кяфер булган кешеләрнең сүзенә охшый. Аллаһ аларны һәлак итсен! Алар никадәр (хактан батыйльгә) тайпылганнар»** («әт-Тәүбә», 30).

اتَّخَذُوا أَحْبَارَهُمْ وَرُهْبَانَهُمْ أَرْبَابًا مِنْ دُونِ اللّٰهِ وَالْمَسِيحَ ابْنَ مَرْيَمَ
وَمَا أُمِرُوا إِلَّا لِيَعْبُدُوا إِلَهًا وَاحِدًا لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ سُبْحَانَهُ عَمَّا يُشْرِكُونَ

**«Алар (яһүдиләр) Аллаһны калдырып, руханиларын һәм монахларны, янә Мәрьям улы Мәсихне (Гайсәне) раббы иттеләр. Югыйсә, аларга бит бер илаһка гына гыйбадәт кылырга әмер ителгән иде, Аннан башка илаһ юк. Ул – аларның ширек кушкан нәрсәләреннән пакь»** («әт-Тәүбә», 31).

Бүгенге яһүдиләр Хәзрәти Гозәерне «Аллаһның улы» дип атауны кабул итмәсәләр дә, ул чордагы бер төркем яһүди Гозәер галәйһис-сәләәмгә карата бик зур кадер-хөрмәттә була һәм аларның кайберләре аны әнә шул кушамат белән искә ала.

# ҮЛГӘННӘН СОҢ ТЕРЕЛҮ

«Бәгъсү бәгъдел-мәүт» үлемнән соң башка үлмәслек итеп терелүне белдерә. Җанның мәңгелеккә сәфәре ул. Кеше, матди һәм рухи яктан караганда, башта табигать элементы булган туфрак сыйфатында яши, күпмедер вакыт атасының мәниендә, аннары берара ана карынында, соңыннан әти-әнинең кулларында, шуннан соң исә аларның күңелендә гомер кичерә. Ниһаять, дөнья бишегеннән кабер бишегенә тапшырылып, зират, кыямәт, җәннәт яки җәһәннәм сәфәренә күчерелә.

Коллары гафләт йокысыннан уянып, хакыйкать дөньясыннан үз өлешләрен ала алсын, Раббыга гыйбадәттә кимчелек җибәрмәсен өчен, Аллаһ Тәгалә күрә һәм ишетә торган йөрәккә ия затларга санап бетермәслек хисапсыз илаһи могҗизалы мисаллар китерә. Алар Коръәни-Кәримдә һәм галәм яшәешендә бөек кодрәтнең чагылышы белән игътибарны җәлеп итә торган, киләчәктә котылгысыз үлеп терелү турында күп-күп хикмәтләрне күз алына китереп бастыра.

Җәнабел-Хак Коръәни-Кәримдә Гозәер галәйһис-сәләәм һәм Әсхабе Кәһфнең гыйбрәтле һәм хикмәтле кыйссаларын кешеләргә «бәгъсү бәгъдел-мәүт»кә бер мисал буларак тәкъдим итә.[157] Әлеге илаһи мисаллар, күңелләрне камилләштереп, Хак Тәгаләгә якынайткан һәм йөрәкне савыктырган хикмәтләрне колачлый.

### Әсхабе Кәһф

Әсхабе Кәһф потларга табынган хөкемдар Дакьянус чорында Тарсуста яшәгән, иман һәм тәүхид дин өчен көрәшкән изге егетләр була.

Әсхабе Кәһфнең саны турында Коръәни-Кәримдә төгәл мәгълүмат бирелми: «Алар бер төркем яшьләр иде», – дип кенә искә алына. Бу исә кыйссада төп басым ясарга теләгән мәсьәләнең бу егетләрнең саны яки яшәгән иле түгел, аерым алганда, ул изге бәндәләрнең иман-ихсан хисе һәм Аллаһ каршында кыйммәтләрен арттырган күңел пакьлеге икәнлеген күрсәтә. Хак иман һәм тәүхид дин өчен потпәрәстлеккә каршы көрәшне ачып биргән гыйбрәтле һәм хикмәтле бу кыйссада, үлгәннән соң кабат терелү үрнәге дә китерелә, шул рәвешле адәм баласына бик күп илаһи хакыйкатьләрне аңлату максаты күз уңында тотыла.

157. Үлгәннән соң терелү турында Коръәни-Кәримдә бирелгән мисалларның тагын берсе – «Бәкара» сүрәсенең 260 нчы аяти-кәримәсендә бәян кылынган кошлар терелү вакыйгасы. Тулырак мәгълүмат өчен карагыз: «Пәйгамбәрләр чылбыры», I том.

Король Дакьянусның якын кешеләреннән бер төркем яшьләр булган Әсхабе Кәһф, тәүхид гакыйдәсенә иярүләре сәбәпле, потпәрәст һәм залим корольләренең золымы бетсен өчен, Җәнабел-Хакка елый-елый гел догада ялвара торган булалар. Ләкин залим король, тәкәбберлеге аркасында имансызлыгын һәм золымын көннән-көн арттырып, үзен тәңре дип игълан итүгә кадәр барып җитә. Моның белән генә туктап калмыйча, тәүхид гакыйдәсен тотучыларның барысын бергә җыеп, аларны бик авыр җәзаларга тартып, шәһәр капкасы янына астыра башлый.

Шулвакыт ул үзенең якын кешеләре булган Әсхабе Кәһфнең дә мөэминнәр икәнлеген белеп ала. Ачудан кабарып, аларны үз янына чакырта да янарга керешә. Ләкин егетләр, иманның мәңгелек тәмен татырга өлгергәнлектән, мондый янаулардан һич куркып калмыйлар һәм, залим хөкемдарга каршы нык торып, хакыйкатьне йөзенә бәреп әйтәләр. Аллаһ Тәгалә аларның бу хәлен түбәндәгечә бәян кыла:

نَحْنُ نَقُصُّ عَلَيْكَ نَبَأَهُمْ بِالْحَقِّ إِنَّهُمْ فِتْيَةٌ آمَنُوا بِرَبِّهِمْ وَزِدْنَاهُمْ هُدًى

**«(И, Рәсүлем!) Без сиңа аларның башыннан кичкәннәрне хак белән сөйлибез. Һичшиксез, алар Раббыларына иман китергән яшьләр иде. Без исә аларның һидәятләрен арттырдык»** («әл-Кәһф», 13).

وَرَبَطْنَا عَلَىٰ قُلُوبِهِمْ إِذْ قَامُوا فَقَالُوا رَبُّنَا رَبُّ السَّمَاوَاتِ
وَالْأَرْضِ لَنْ نَدْعُوَ مِنْ دُونِهِ إِلَهًا لَقَدْ قُلْنَا إِذًا شَطَطًا

**«Алар (залим хөкемдарлары каршында) аягөсте торып баскач, Без аларның күңелләренә куәт бирдек, шул сәбәпле алар әйттеләр: “Безнең Раббыбыз – күкләрнең һәм җирнең Раббысы. Без Аннан башканы илаһ дип әйтмибез. Юкса, (дөреслектән) ерак сүз әйткән булырбыз”»** («әл-Кәһф», 14).

هَؤُلَاءِ قَوْمُنَا اتَّخَذُوا مِنْ دُونِهِ آلِهَةً لَوْلَا يَأْتُونَ عَلَيْهِمْ
بِسُلْطَانٍ بَيِّنٍ فَمَنْ أَظْلَمُ مِمَّنِ افْتَرَىٰ عَلَى اللَّهِ كَذِبًا

**«Безнең кавемебез Аннан (Аллаһтан) башка илаһлар сайлады. Алар хакында ачык бер дәлил китерсәләр иде! Аллаһка карата ялган уйдырма чыгарудан да залимрәк кем бар?»** («әл-Кәһф», 15).

Егетләр Дакьянусның бик үҗәтләнеп потларга табынырга тәкъдим итүенә каршы болай дип җавап бирә: «Безнең бер илаһыбыз бар, Аннан башканы илаһ дип танымыйбыз. Без, җирләрнең һәм күкләрнең Раббысыннан баш тартып, коллар ясаган җансыз таш кисәкләренә һич табынмыйбыз. Синең

тәкъдимеңне кабул итү ихтималыбыз бөтенләй юк! Нинди хөкем чыгарасың килсә, шулай эшли аласың!»

Әүвәл Муса галәйһис-сәләәм белән ярышка чыккан, соңыннан исә иман белән хөрмәтләнгән сихерчеләр Фиргавен каршында нинди иман ныклыгы һәм чыдамлык үрнәге күрсәткән булса, шуңа тиң ныклык-чыдамлыкны Әсхабе Кәһф залим король Дакьянус каршында күрсәтә. Сихерчеләр дә үзләренә иман бәхете насыйп булгач, Фиргавеннең янавына каршы: «Синең гамәлләрең безгә бер зыян да китерә алмас! Чөнки без, насыйп кылса, Раббыбызга кайтарылачакбыз! Теләгәнеңне эшли аласың!» – дип җавап бирәләр.

Хөкемдар Дакьянус, иманлы яшьләрнең үз-үзләрен шулай кыю тотышын күреп, ачудан шартлар дәрәҗәгә җитә. Ул аларга элек биргән дәрәҗә-исемнәрнең барысын да кире тартып ала. Аннары: «Сез яшь әле, үзегезне кызганыгыз! Кылганнарыгыздан баш тартыр өчен, сезгә өч көн вакыт бирәм! Уйлагыз, нәтиҗә ясагыз: котылунымы, әллә инде сезне һәлак итүемне сайлыйсызмы?» – дип янап куя. Шуннан соң аларны үз ихтыярларына калдырып, Ниновага китеп бара.

Хөкемдар биргән бу срок Әсхабе Кәһф өчен чын-чынлап бер илаһи рәхмәт була: аларга залим хөкемдарның явызлыгыннан котылу өчен вакыт табыла. Җәнабел-Хакның рәхмәте һәм ярдәменә өметләнгән бу егетләрнең янында бер эт тә була. Бергәләп шәһәрдән качып, алар бер мәгарәгә яшеренә. Бу тау куышында өйләреннән алып килгән ризыкларны ашыйлар һәм төн-көн Җәнабел-Хакка гыйбадәт кылалар һәм: «Раббыбыз! Безгә үз тарафыңнан рәхмәт бир һәм безгә бу хәлебездән бер котылу юлын ирештер!» – дип, ялвара-ялвара, Аңа сыеналар.

Риваятькә күрә, Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә һиҗрәт вакытында яшеренгән Сәвер мәгарәсендә Җәнабел-Хакка шул ук дога белән мөрәҗәгать итә.

Изге гамәлләре, ихласлыклары һәм укыган догалары хөрмәтенә Әсхабе Кәһфкә рәхмәтле Аллаһ ярдәме ирешә. Ул арада залим Дакьянус Ниновадан кайтып, боларның хәл-әхвәлләрен белешә. Патша шундук егетләрнең эзенә төшеп, алар яшеренгән мәгарәне таба. Ачуыннан котырып, нинди җәза бирәчәген уйлаган чакта, Аллаһ Тәгалә аның акылына мәгарә авызын каплату фикерен китерә. Артык баш катырып тормыйча, Дакьянус гаскәрләренә: «Хәзер үк мәгарәнең тишеген томалагыз! Ачлыктан-сусызлыктан интегеп үлсеннәр; мәгарә алар өчен кабергә әйләнсен!» – дип боера. Шул рәвешле ул изге егетләрне үзенә күрә терелә́й күмеп җәзаларга ниятли. Ләкин явыз патша шуны белми: Хәзрәти Мусаны Фиргавеннең сараенда үстереп, аның золымыннан аралаган Аллаһ Әсхабе Кәһфне дә Дакьянусның явызлыгыннан саклый. «Саклаучыларның иң хәерлесе» булган Җәнабел-Хак Әсхабе Кәһфне

Үзенең чиксез рәхмәтенә төрә һәм аларны 309 ел тау куышында җанлы килеш йоклата.

Хәзрәти Мәүләна Җәләлетдин Руми әйтә:

«Гафилләр арасында булып, аларның йогынтысына бирелүгә караганда, йоклавың яхшырак. Җәнабел-Хак, Әсхабе Кәһфне фасыйклар арасыннан аерып, йөрәкләрен гафләттән саклаган».

Аяти кәримәләрдә болай дип әйтелә:

وَتَرَى الشَّمْسَ إِذَا طَلَعَتْ تَزَاوَرُ عَنْ كَهْفِهِمْ ذَاتَ الْيَمِينِ وَإِذَا غَرَبَتْ تَقْرِضُهُمْ ذَاتَ الشِّمَالِ وَهُمْ فِي فَجْوَةٍ مِنْهُ ذَلِكَ مِنْ آيَاتِ اللَّهِ مَنْ يَهْدِ اللَّهُ فَهُوَ الْمُهْتَدِ وَمَنْ يُضْلِلْ فَلَنْ تَجِدَ لَهُ وَلِيًّا مُرْشِدًا

**«(И, Рәсүлем! Анда булсаң) Кояшны күрер идең. Чыккан чагында ул мәгарәләренең уң ягына борыла, баеган чагында исә (аларга тимичә) сул ягыннан үтеп китә иде. Алар аның (кояш яктысыннан интекмичә) иркен бер урынында иделәр. Менә бу – Аллаһның могҗизаларыннан (Аның бөеклегенең бер күренеше). Аллаһ кемне дә булса һидәяткә ирештерсә, ул, һичшиксез, һидәятне тапкан булыр, кемне дә булса адаштырса, аны туры юлга юнәлтерлек бер дус та, яклаучы да таба алмассың!»** («әл-Кәһф», 17).

وَتَحْسَبُهُمْ أَيْقَاظًا وَهُمْ رُقُودٌ وَنُقَلِّبُهُمْ ذَاتَ الْيَمِينِ وَذَاتَ الشِّمَالِ وَكَلْبُهُمْ بَاسِطٌ ذِرَاعَيْهِ بِالْوَصِيدِ لَوِ اطَّلَعْتَ عَلَيْهِمْ لَوَلَّيْتَ مِنْهُمْ فِرَارًا وَلَمُلِئْتَ مِنْهُمْ رُعْبًا

**«Син аларны уяу дип санарсың, әмма алар йоклыйлар. Без аларны әле уң якка, әле сул якка әйләндерә идек. Этләре дә алда (мәгарә авызында) алгы аякларын сузып ята иде. Әгәр аларны күрә алган булсаң, һичшиксез, алардан йөз чөерер һәм алар аркасында курку эчендә булыр идең»** («әл-Кәһф», 18).

Җәнабел-Хак Әсхабе Кәһфне уятканда, алар мәгарәдә үзләрен бик аз гына вакыт торган, дип уйлыйлар. Аяти кәримәләрдә бу хакта болай дип хәбәр ителә:

وَكَذَلِكَ بَعَثْنَاهُمْ لِيَتَسَاءَلُوا بَيْنَهُمْ قَالَ قَائِلٌ مِنْهُمْ كَمْ لَبِثْتُمْ قَالُوا لَبِثْنَا يَوْمًا أَوْ بَعْضَ يَوْمٍ قَالُوا رَبُّكُمْ أَعْلَمُ بِمَا لَبِثْتُمْ فَابْعَثُوا أَحَدَكُمْ بِوَرِقِكُمْ هَذِهِ إِلَى الْمَدِينَةِ فَلْيَنْظُرْ أَيُّهَا أَزْكَى طَعَامًا فَلْيَأْتِكُمْ بِرِزْقٍ مِنْهُ وَلْيَتَلَطَّفْ وَلَا يُشْعِرَنَّ بِكُمْ أَحَدًا

**«Бер-берләреннән сорасыннар дип, Без аларны уяттык. Араларыннан берсе: “Никадәр булдыгыз?” – диде. Алар (берсе): “Бер көн яки бер көннән азрак”, – диделәр. Алар (кайсыдыр) әйттеләр: “Күпме калга-**

**ныгызны Раббыгыз яхшырак белә. Арагыздан берегезне шушы көмеш тәңкәләр белән шәһәргә җибәрегез, алсын, (шәһәрдә) нинди ризык иң пакь булса, шуннан сезгә алып килсен. Әмма бик сак булып (яшеренеп) эш итсен һәм сезнең хакта һичкем сизенмәсен!"»** («әл-Кәһф», 19).

إِنَّهُمْ إِنْ يَظْهَرُوا عَلَيْكُمْ يَرْجُمُوكُمْ أَوْ يُعِيدُوكُمْ فِي مِلَّتِهِمْ وَلَنْ تُفْلِحُوا إِذًا أَبَدًا

**«Һичшиксез, әгәр алар сезнең хакта белеп алсалар, сезне таш атып үтерәчәкләр яки үз диннәренә кертәчәкләр. Ул чакта беркайчан да котылуга ирешмәячәксез»** («әл-Кәһф», 20).

Аларның берсе шәһәргә ризык алырга киткәч, аның кулында әллә ничә гасыр элекке акчаларны күрүчеләр, бу егетнең берәр хәзинә тапкан, дип уйлап, хөкемдарга шикаять белән хәбәр салалар.

Ул заманның яңа хөкемдары исә изге кеше була. Ул үз тирәсендәгеләргә һәрвакыт матур-матур вәгазь-нәсыйхәтләр сөйли, аларны тәүхид дингә өнди, «бәгъсү бәгъдел-мәүт», кыямәт купкач, кабат терелү серләре турында аңлата. Тик аңа буйсынган халыкның наданнары үлгәннән соң терелүгә шикләнеп карый, моңа һич ышанмыйлар. Патша моңа бик кайгыра һәм Җәнабел-Хакка: «Йә, Раббы! Бу кавемгә алар инкяр иткән хакыйкатькә бәйле берәр дәлил күрсәт!» – дип ялвара.

Ниһаять, Әсхабе Кәһфнең берсе булган егетне каршында күргәч, шатланып, бу хакта үз тирәсендәгеләргә игълан итә, үзе көткән-эзләгән күренешнең тормышка ашуы сәбәпле, Җәнабел-Хакка хәмед-сәнәләр әйтә. Аннары Әсхабе Кәһф янына барып, аларны зиярәт кыла. Шул рәвешле илаһи хикмәт һәм гыйбрәтләр чынга аша. Шуннан соң Җәнабел-Хак Әсхабе Кәһфнең җаннарын ала.

Әсхабе Кәһф, иманнарында ныклык, золымга карата түземлек күрсәтүләре, Аллаһ юлыннан тайпылмаулары һәм шуның өчен һиҗрәт кылуларының бер бәрәкәте буларак, Коръәни-Кәримдә хөрмәтләп искә алыналар. Бу кыйссага мөнәсәбәтле рәвештә Коръәни-Кәримдәге бер сүрә шушы изге бәндәләргә бәйле исем белән аталган, сүз «Кәһф» сүрәсе турында бара. Бу сүрәдә Әсхабе Кәһф белән бәйле бәяннан кала да башка әһәмиятле кыйссалар да урын алган. Шуңа карамастан сүрәгә нәкъ менә шушы исем бирелүе әлеге кыйссаның аерым бер әһәмиятенә басым ясый.

Пәйгамбәр Әфәндебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм җомга көнне «Кәһф» сүрәсе уку киләсе җомгага кадәрге гөнаһларга кәффарәт булачагын белдергән.[158] Бу сүрә иман өчен көрәш, «бәгъсү бәгъдел-мәүт», Муса белән Хозыр кыйссасы, илаһи бөеклек һәм кодрәт күренешләре кебек һәрчак хәтердә тоту тиешле мөһим мәсьәләләрне колачлаганга күрә, Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм аны һәр атна укырга киңәш иткән.

158. Карагыз: Сүюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», I, 98.

Икенче яктан караганда шунысы да игътибарны җәлеп итә: Әсхабе Кәһф янында булган эт тә алар лаек булган илаһи нигъмәттән өлеш ала. Мөфәссирләр аңлатуынча, Әсхабе Кәһфнең Кыйтмире, эт булса да, тугры затлар белән бергә йөрү һәм мәгарә авызын тугрылык белән саклап, аларга хезмәт итүе бәрәкәте бәрабәренә җәннәткә керәчәк.[159]

Хәзрәти Мәүләна болай дип яза: «Ул эт үзен Әсхабе Кәһфне тугрылык белән саклауга багышлаган өчен, мәгарә авызы алдында илаһи рәхмәт суын Аллаһны танып-белүчеләр кебек эчеп, җәннәттә дә шулар белән бергә булу хакын яулады».

Шәех Сади бу хакта: «Фасыйклар белән бергә булганга күрә, Лут галәйһис-сәләәмнең хатыны үз дәрәҗәсен төшерә, бозыклыкка бата. Әсхабе Кәһфнең Кыйтмире исә, изгеләрне саклаган өчен, хайванлыктан котылып, кешегә хас сыйфатлар алуга ирешә», – дип әйтә.

Җәнабел-Хак, Әсхабе Кәһф кыйссасында бер яктан 309 ел ризыксыз, сусыз, әмма тере хәлдә йоклатуга бәйле күренешнең хикмәтләрен ачыкласа, икенче яктан исә моның Үзе өчен бик җиңел икәненә игътибар юнәлтә:

أَمْ حَسِبْتَ أَنَّ أَصْحَابَ الْكَهْفِ وَالرَّقِيمِ كَانُوا مِنْ آيَاتِنَا عَجَبًا

**«(И, Рәсүлем!) Әллә син мәгарә һәм рәкыйм әһелләренең Безнең аятьләребез арасыннан иң гаҗәеп нәрсә булды, дип саныйсыңмы?»** («әл-Кәһф», 9).

Чөнки Җәнабел-Хак моннан да зуррак күренешләрне чынга ашырып, алар белән идарә итәргә кодрәтле. Ул – юктан бар итүче, үтерүче һәм терелтүче.

Аллаһ Тәгалә көн саен төрле-төрле күренешләр белән кешегә аның бар ителеше һәм үлеме турында хәтерләтеп тора, үлгәннән соң терелүне дә төшенсен өчен, акыл һәм йөрәк тоярга тиешле хикмәтләр тулы аяти кәримәләрдә мәгълүм кыйссалар белән бергә «бәгъсү бәгъдел-мәүт»нең гаделлеген, Үз бөеклеген һәм кодрәтен искә төшереп, болай ди:

أَوَلَمْ يَرَ الْإِنْسَانُ أَنَّا خَلَقْنَاهُ مِنْ نُطْفَةٍ فَإِذَا هُوَ خَصِيمٌ مُبِينٌ وَضَرَبَ لَنَا مَثَلًا وَنَسِيَ خَلْقَهُ
قَالَ مَنْ يُحْيِي الْعِظَامَ وَهِيَ رَمِيمٌ قُلْ يُحْيِيهَا الَّذِيأَنْشَأَهَا أَوَّلَ مَرَّةٍ وَهُوَ بِكُلِّ خَلْقٍ عَلِيمٌ

**«Кеше Безнең аны бер тамчыдан яралтканыбызны күрмиме әллә? (Бер карыйсың), ул ап-ачык дошманлык күрсәтә. Үзенең яралтылганын онытып, Безгә мисал китерә һәм: “Бу череп беткән сөякләрне кем терелтәчәк?” – дип әйтә. (И, Рәсүлем!) Әйт: “Аларны беренче мәртәбә Яралтучы терелтәчәк. Ул бит һәр яралтылган нәрсәне белүче”»** («Йәсин», 77–79).

159. Карагыз: И. Хаккы Бурсәви, «Рухул-Бәян», V, 226.

أَيَحْسَبُ الْإِنْسَانُ أَلَّنْ نَجْمَعَ عِظَامَهُ بَلَىٰ قَادِرِينَ عَلَىٰ أَنْ نُسَوِّيَ بَنَانَهُ

**«Кеше Без аның сөякләрен җыя алмаячакбыз дип саныймы әллә? Әйе! Бармакларын (әүвәлге хәлендә) җыярга көчебездән килә»** («әл-Кыямә», 3–4).

أَلَيْسَ ذَٰلِكَ بِقَادِرٍ عَلَىٰ أَنْ يُحْيِيَ الْمَوْتَىٰ

**«Әллә бу Зат (боларны эшләгән Аллаһ) үлеләрне терелтергә кодрәтле түгелме?»** («әл-Кыямә», 40).

Җәнабел-Хак үлеләрне терелтүнең Аның өчен бик гади бер гамәл икәнлеген, акылга һәм хис-тойгы йөрәк ияләренә дөньяда билгеле тәртипле күренешләрдән үрнәкләр китереп аңлата:

زَعَمَ الَّذِينَ كَفَرُوا أَنْ لَنْ يُبْعَثُوا قُلْ بَلَىٰ وَرَبِّي لَتُبْعَثُنَّ ثُمَّ لَتُنَبَّؤُنَّ بِمَا عَمِلْتُمْ وَذَٰلِكَ عَلَى اللَّهِ يَسِيرٌ

**«(И, Рәсүлем!) Кяферләр беркайчан да терелтелмәячәкләр дип саныйлар. Әйт: “Юк! Раббым белән ант итәмен, сез тулысынча терелтеләчәксез, шуннан соң кылган нәрсәләрегездән хәбәрдар ителәчәксез. Аллаһ өчен бу бик җиңел”»** («әт-Тәгабун», 7).

وَاللَّهُ أَنْبَتَكُمْ مِنَ الْأَرْضِ نَبَاتًا ثُمَّ يُعِيدُكُمْ فِيهَا وَيُخْرِجُكُمْ إِخْرَاجً

**«(Онытмагыз), Аллаһ сезне җирдән үсемлек кебек үстерде. Шуннан соң аның эченә кайтарачак (ягъни үтерәчәк) һәм сезне бер чыгарылыш белән чыгарачак (терелтәчәк)»** («Нух», 17–18).

وَهُوَ الَّذِي يُرْسِلُ الرِّيَاحَ بُشْرًا بَيْنَ يَدَيْ رَحْمَتِهِ حَتَّىٰ إِذَا أَقَلَّتْ سَحَابًا ثِقَالًا سُقْنَاهُ لِبَلَدٍ
مَيِّتٍ فَأَنْزَلْنَا بِهِ الْمَاءَ فَأَخْرَجْنَا بِهِ مِنْ كُلِّ الثَّمَرَاتِ كَذَٰلِكَ نُخْرِجُ الْمَوْتَىٰ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ

**«Ул – рәхмәте алдыннан сөендерүчеләр итеп җилләрне җибәрүче. Аннары алар (ул җилләр), авыр-авыр болытларны алып килгәч, Без аны үлгән бер өлкәгә куабыз, суны яудырабыз һәм, аның сәбәпле, җимешләрнең бөтенесен үстерәбез. Үлеләрне дә шулай терелтәчәкбез. Бәлки, сез уйларсыз!»** («әл-Әгъраф», 57).

فَانْظُرْ إِلَىٰ آثَارِ رَحْمَتِ اللَّهِ كَيْفَ يُحْيِي الْأَرْضَ بَعْدَ مَوْتِهَا
إِنَّ ذَٰلِكَ لَمُحْيِي الْمَوْتَىٰ وَهُوَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

**«Син Аллаһ рәхмәтенең әсәрләренә кара, Ул туфракны (кыш фасылындагы) үлеме артыннан (яз көне) ничек терелтә! Һичшиксез, Ул үлеләрне терелтүче һәм Ул һәрнәрсәгә кодрәтле»** («әр-Рум», 50).

أَوَلَمْ يَرَوْا أَنَّ اللهَ الَّذِي خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ وَلَمْ يَعْيَ بِخَلْقِهِنَّ
بِقَادِرٍ عَلَىٰ أَنْ يُحْيِيَ الْمَوْتَىٰ بَلَىٰ إِنَّهُ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

**«Күкләрне һәм җирне яралткан һәм аларны яралтуда һич арымаган Аллаһның үлеләрне терелтергә кодрәте җиткәнен күрмәделәрме әллә? Әйе! Һичшиксез, Ул – һәрнәрсәгә кодрәтле»** («әл-Әхкәф», 33).

قُلْ كُونُوا حِجَارَةً أَوْ حَدِيدًاأَوْ خَلْقًا مِمَّا يَكْبُرُ فِي صُدُورِكُمْ فَسَيَقُولُونَ مَنْ يُعِيدُنَا قُلِ الَّذِي
فَطَرَكُمْ أَوَّلَ مَرَّةٍ فَسَيُنْغِضُونَ إِلَيْكَ رُءُوسَهُمْ وَيَقُولُونَ مَتَىٰ هُوَ قُلْ عَسَىٰ أَنْ يَكُونَ قَرِيبًا

**«Әйт: “Таш яки тимер булсагыз да! Яки күңелләрегездә (яңадан терелүе мөмкин күренмәгән) зур бер барлык булсагыз да” (Болар Аллаһның сезне яңадан терелтүен кыенлаштырмас). Алар: “Алайса кем безне (тормышка) кире кайтарачак?” – диячәкләр. Син: “Сезне беренче мәртәбә юктан бар кылучы”, – диген. Шулвакыт алар сиңа башларын селкеп: ”Кайчан соң бу?” – диячәкләр. Әйт: “Бик тиздән булса кирәк!”»** («әл-Исра», 50–51).

أَوَلَمْ يَرَوْا أَنَّ اللهَ الَّذِي خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ قَادِرٌ عَلَىٰ أَنْ يَخْلُقَ
مِثْلَهُمْ وَجَعَلَ لَهُمْ أَجَلًا لَا رَيْبَ فِيهِ فَأَبَى الظَّالِمُونَ إِلَّا كُفُورًا

**«Әллә алар күкләрне һәм җирне яралткан Аллаһ аларга охшашларны яралтырга (үлгәннән соң терелтергә) кодрәтле булганын белмиләрме? Ул алар өчен бернинди шик булмаган бер әҗәл вакыты билгеләде. Әмма залимнәр көферлектән башка һәрнәрсәне кире кагалар»** («әл-Исра», 99).

إِنَّمَا قَوْلُنَا لِشَيْءٍ إِذَا أَرَدْنَاهُ أَنْ نَقُولَ لَهُ كُنْ فَيَكُونُ

**«Без берәр нәрсәне теләгән чакта, аңа “Бар бул!” – дип әйтәбез, һәм ул шунда ук барлыкка килә»** («ән-Нәхел», 40).

Җәнабел-Хак төнлә йоклавыбыз һәм иртән уянуыбызның да үлем белән терелүгә бер мисал икәнен түбәндәге аяти кәримәдә бик күркәм аңлата:

وَهُوَ الَّذِي يَتَوَفَّاكُمْ بِاللَّيْلِ وَيَعْلَمُ مَا جَرَحْتُمْ بِالنَّهَارِ ثُمَّ يَبْعَثُكُمْ فِيهِ لِيُقْضَىٰ أَجَلٌ
مُسَمًّى ثُمَّ إِلَيْهِ مَرْجِعُكُمْ ثُمَّ يُنَبِّئُكُمْ بِمَا كُنْتُمْ تَعْمَلُونَ

**«Ул – сезне төнлә алучы (җаныгызны алгандай йоклатучы), көндез ни кылганнарыгызны белүче Зат. Шуннан соң билгеләнгән вакыт тулсын дип, сезне анда терелтә (уята). Соң кайтуыгыз Аңа гына булачак һәм шуннан Ул кылган нәрсәләрегезне сезгә хәбәр итәчәк»** («әл-Әнгам», 60).

Аяти кәримәләрдә әйтелгәнчә, көннең төнгә, төннең көнгә әйләнүе, дөньяда ел фасылларының бер-берсе артыннан килүе һәм шул вакытта туфракта бара торган үлемнәр, терелүләр һ.б. күренешләрнең һәркайсы асылда кыямәт таңында торып басуны белдергән «бәгъсү бәгъдел-мәүт»не хәтергә төшерердәй гыйбрәтле хакыйкатьләр булып тора.

Хак Тәгалә үлемнән соң терелү хакыйкатен йөрәкләрдә иң вак шик-шөбһәгә дә урын калдырмаячак ачыклык һәм төрле дәлилләр белән, кеше аңы җитәрлек рәвештә күп кенә аяти кәримәләрдә белдерә. Бу мәсьәлә белән бәйле аяти кәримәләрдә мондый ачыкламалар да бар:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنْ كُنْتُمْ فِي رَيْبٍ مِنَ الْبَعْثِ فَإِنَّا خَلَقْنَاكُمْ مِنْ تُرَابٍ ثُمَّ مِنْ نُطْفَةٍ ثُمَّ مِنْ عَلَقَةٍ ثُمَّ مِنْ مُضْغَةٍ مُخَلَّقَةٍ وَغَيْرِ مُخَلَّقَةٍ لِنُبَيِّنَ لَكُمْ وَنُقِرُّ فِي الْأَرْحَامِ مَا نَشَاءُ إِلَىٰ أَجَلٍ مُسَمًّى ثُمَّ نُخْرِجُكُمْ طِفْلًا ثُمَّ لِتَبْلُغُوا أَشُدَّكُمْ وَمِنْكُمْ مَنْ يُتَوَفَّىٰ وَمِنْكُمْ مَنْ يُرَدُّ إِلَىٰ أَرْذَلِ الْعُمُرِ لِكَيْلَا يَعْلَمَ مِنْ بَعْدِ عِلْمٍ شَيْئًا وَتَرَى الْأَرْضَ هَامِدَةً فَإِذَا أَنْزَلْنَا عَلَيْهَا الْمَاءَ اهْتَزَّتْ وَرَبَتْ وَأَنْبَتَتْ مِنْ كُلِّ زَوْجٍ بَهِيجٍ

**«И, кешеләр! Әгәр терелтелүдән шөбһәләнсәгез. Без бит сезне туфрактан, шуннан соң су тамчысыннан, шуннан соң оешкан каннан (аталанган күкәй күзәнәктән), шуннан шәкеле (әүвәл) билгесез, (аннары) билгеле (очлыклары вакыт узу белән формалашкан) бер ит кисәгеннән яралттык ки, сезгә (кодрәтебезне) ачык итеп аңлатабыз. Без теләгәнебезне аналыкларда билгеләнгән вакытка кадәр тотабыз, шуннан соң сезне бәбиләр хәлендә чыгарабыз. Шуннан көчле чагыгызга ирешүегез өчен (сезне үстерәбез). Арагыздан вафат булганнар да бар, белгәннән соң берни дә белмәгән картаю чорына кайтканнар да бар. Син туфракны үле һәм коры хәлдә күрәсең. Без аның өстенә су (яңгыр) иңдергәч, ул хәрәкәтләнә, кабара һәм күркәм парлар (үсемлекләр) үстерә»** («әл-Хаҗ», 5).

ذَٰلِكَ بِأَنَّ اللَّهَ هُوَ الْحَقُّ وَأَنَّهُ يُحْيِي الْمَوْتَىٰ وَأَنَّهُ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

**«Бу шул сәбәпле ки, Аллаһ – Хакның үзе. Һичшиксез, Ул үлеләрне терелтә һәм Ул һәрнәрсәгә кодрәтле»** («әл-Хаҗ», 6).

وَأَنَّ السَّاعَةَ آتِيَةٌ لَا رَيْبَ فِيهَا وَأَنَّ اللَّهَ يَبْعَثُ مَنْ فِي الْقُبُورِ

**«Һәм шул сәбәпле, Сәгать (Кыямәт), һичшиксез, киләчәк, аңарда бернинди дә шик юк. Һәм дә Аллаһ каберләрдәгеләрне терелтәчәк (күтәрәчәк)»** («әл-Хаҗ», 7).

«Бәгъсү бәгъдел-мәүт»нең тәүге сәхифәсе Сурга беренче тапкыр өрелгәч ачыла. Әлеге сур тавышы яңгырагач, һәркем үләчәк. Соңрак, Сурга икенче тапкыр өрелгәч, «бәгъсү бәгъдел-мәүт» вакыйгасы чынга ашачак. Аллаһ Тәгалә бу хакыйкатьне болай тасвирлый:

وَنُفِخَ فِي الصُّورِ فَصَعِقَ مَنْ فِي السَّمَاوَاتِ وَمَنْ فِي الْأَرْضِ
إِلَّا مَنْ شَاءَ اللَّهُ ثُمَّ نُفِخَ فِيهِ أُخْرَىٰ فَإِذَا هُمْ قِيَامٌ يَنْظُرُونَ

**«Сурга өрелер дә, Аллаһ теләгәннәрдән тыш, күкләрдә булганнар һәм җирдә булганнар үләр. Шуннан соң, аңа тагын бер мәртәбә өрелер, алар торып басарлар һәм каранып торырлар!»** («әз-Зүмәр», 68).

Җәнабел-Хак ул көнне «бәгъсү бәгъдел-мәүт» нәтиҗәсендә терелгән кешеләрнең коты очуын һәм мәхшәрнең дәһшәте турында да телгә ала:

يَوْمَ يَخْرُجُونَ مِنَ الْأَجْدَاثِ سِرَاعًا كَأَنَّهُمْ إِلَىٰ نُصُبٍ يُوفِضُونَ خَاشِعَةً أَبْصَارُهُمْ
تَرْهَقُهُمْ ذِلَّةٌ ذَٰلِكَ الْيَوْمُ الَّذِي كَانُوا يُوعَدُون

**«Ул көнне алар, утыртып куелган потларга таба ашыккан кебек, каберләрдән кабалана-кабалана чыгачаклар. Күзләре түбән төшкән хәлдә. Аларны хурлык каплап алачак. Бу – аларга вәгъдә ителгән көн иде!»** («әл-Мәгариҗ», 43–44).

فَيَوْمَئِذٍ لَا يَنْفَعُ الَّذِينَ ظَلَمُوا مَعْذِرَتُهُمْ وَلَا هُمْ يُسْتَعْتَبُونَ

**«Ул көнне залим булган кешеләргә гафу үтенүләре файда китермәячәк һәм алардан (үкенеп, тәүбә итеп, Аллаһны) разый итәр өчен, берни дә соралмаячак»** («әр-Рум», 57).

يَوْمَ تَشَقَّقُ الْأَرْضُ عَنْهُمْ سِرَاعًا ذَٰلِكَ حَشْرٌ عَلَيْنَا يَسِيرٌ

**«Ашыккан хәлдә, туфрак алардан ярылып аерыласы (чыгарыласы) көнне. Бу – безнең өчен бик җиңел терелтеп туплау»** («Каф», 44).

يَوْمَ يَفِرُّ الْمَرْءُ مِنْ أَخِيهِ وَأُمِّهِ وَأَبِيهِ وَصَاحِبَتِهِ وَبَنِيهِ لِكُلِّ امْرِئٍ مِنْهُمْ يَوْمَئِذٍ شَأْنٌ يُغْنِيهِ وُجُوهٌ يَوْمَئِذٍ
مُسْفِرَةٌ ضَاحِكَةٌ مُسْتَبْشِرَةٌ وَوُجُوهٌ يَوْمَئِذٍ عَلَيْهَا غَبَرَةٌ تَرْهَقُهَا قَتَرَةٌ أُولَئِكَ هُمُ الْكَفَرَةُ الْفَجَرَةُ

**«Ул көнне кеше үзенең кардәшеннән качачак. Анасыннан һәм атасыннан да. Хатынынннан һәм улларыннан да. Ул көнне алардан һәркайсының үз эше җитәрлек. Кайбер йөзләр ул көнне балкырлар. Көләрләр һәм сөенерләр. Кайбер чырайларда исә ул көнне тузан булачак. Аларны каралык һәм караңгылык каплаячак. Алар – кяферләр һәм гөнаһлылар»** («Габәсә», 34–42).

يَوْمَ تَبْيَضُّ وُجُوهٌ وَتَسْوَدُّ وُجُوهٌ فَأَمَّا الَّذِينَ اسْوَدَّتْ وُجُوهُهُمْ أَكَفَرْتُمْ بَعْدَ إِيمَانِكُمْ فَذُوقُوا الْعَذَابَ بِمَا كُنْتُمْ تَكْفُرُونَ وَأَمَّا الَّذِينَ ابْيَضَّتْ وُجُوهُهُمْ فَفِي رَحْمَةِ اللَّهِ هُمْ فِيهَا خَالِدُونَ

**«(И, кешеләр!) Кайбер йөзләр агарачак, кайбер йөзләр каралачак көнне (үлем килгәнче уйлагыз). Йөзләре кап-кара булганнарга килгәндә исә: “Иманга килүегездән соң кяфер булдыгызмы? Алайса инкяр итүегез өчен газапны татыгыз!” (дип әйтелер). Әмма йөзләре ап-ак булган кешеләр – Аллаһның рәхмәте эчендә. Алар анда мәңге калачак»** («Әли Гыймран», 106–107).

Гадел, дөрес фикерләү сәләтенә ия кеше уйлап карамыймы: галәмдә һәрнәрсә – бер бөртек орлыкның шытып ярылуыннан башлап, җәйге хозурлыкка, туулардан үлемгә, микрогаләмнән макрогаләмгә, атомнардан планеталарга кадәр тулысынча аңлап бетерә алмаслык бер тәртип эчендә кыямәткәчә чиксез бер гармония белән дәвам итәчәк. Бу аһәңне бар итүче Аллаһ Җәллә Җәләлүһү дөньяда кеше акылын гаҗиз калдырган шушы мөкәммәл тәртип һәм илаһи хакимлек эчендә адәм баласын хикмәтсез генә яралтканмы?

Аяти кәримәләрдә болай диелә:

أَفَحَسِبْتُمْ أَنَّمَا خَلَقْنَاكُمْ عَبَثًا وَأَنَّكُمْ إِلَيْنَا لَا تُرْجَعُونَ

**«Сез Без сезне күңел ачар өчен яралттык һәм сез Безгә кайтарылмаячаксыз дип санадыгызмы әллә?»** («әл-Мүэминүн», 115).

أَيَحْسَبُ الْإِنْسَانُ أَنْ يُتْرَكَ سُدًى

**«Әллә кеше караучысыз калдырылган дип саныймы?»** («әл-Кыямә», 36).

Дөньяда һәр атом, Коръәндә һәр хәреф һәм кешедә һәр күзәнәк һичнәрсәнең телсез, әпә яралтылмаганлыгын үзенә генә хас бер тел белән әйтеп торганда, кешенең гафләт йокысына чумып, илаһи хикмәт һәм хакыйкатьләргә ваемсыз калуы ни гаҗәп! Шаккаткыч! Йокыга талган затлар бер-берсеннән ни ала алсын?! Гафләт ияләре дөньясы балаларның күзләрен бәйләп «сукыр тәкә» уенын уйнап йөрүеннән һич аерылмый.

Хакыйкатькә карата сукыр йөрәкләр пәйгамбәрләр һәм әүлияларның аларга ыргыткан коткару бөжраларын, үзләренең нәфес һәм тән теләкләренә туры килмәгәнгә күрә, кире кагып киләләр. Акылларының гаять тар чикләре эчендә үлемнән ерак хыял дөньясы тудырырга тырышып, шул хыял галәмендә буш юанычларга канәгатьләнәләр. Чебеннәр калдык-постык өстендә шатланып, тукланып йөргән кебек, нәҗес тулы дөньяларында бозыклыкларын бәхет дип күреп, тере мәетләр хәлендә гәүдәләрен ташучы йөкче булып яшиләр һәм бакыйлыкка күчәләр. Сыртлары беркайчан да туфракка тимәгән күпме бәдбәхет үлемнең аяусыз йодрыгы суккач, җирләргә сузылып ятачак!..

Дөнья уенчыкларыннан котылып, күңел мохитенә керүчеләр өчен үлем чын тормышның башлангыч ноктасы була. Үлем – шәүләләр дөньясыннан асыл галәмгә күчеш ул. Әгәр үлемнән качу һәм курку шарт икән, кич җиткән саен куркудан калтырана башларга тиешбез. Югыйсә төнге серләргә чумганда, күңелебездә бер курку да тоймыйбыз, чөнки таңның атачагын галәм әйләнеше кагыйдәсе, илаһи тәртип чагылышы буларак беләбез. Ул очракта үлем кочагыннан хакыйкать таңында торачагыбызның да табигый кабул ителүе тиеш. Үткән заманга әйләнеп узып киткән һәр мизгелнең безне хакыйкать таңына якынайтуын аяти кәримә бик матур белдергән:

وَمَنْ نُعَمِّرْهُ نُنَكِّسْهُ فِي الْخَلْقِ أَفَلَا يَعْقِلُونَ

**«Без кемгәдер озын гомер бирсәк, аның яралтылышта (яшьлеген һәм матурлыгын бозып) киресен әйләндерәбез. Әллә алар (сәфәр кайсы юнәлештә икәнен) аңламыйлармы?»** («Йәсин», 68).

Бер күренекле фикер иясе сүзләре белән әйткәндә: «Дөнья акыл ияләре өчен Хак Тәгаләне күзәтүдән (илаһи күренешләр, илаһи тәртип һәм сәнгатькә сокланып, ләззәт алу һәм хисләнүдән), ахмаклар өчен исә ашау һәм шәһвәттән гыйбарәт». Адәм баласының тормозы тотмаган автомобиль кебек тәгәрәгән гомер арбасына, әҗәл җилләренә, көзге манзараларга игътибарсыз булып, бу галәмне ахмак, кыяфәтсез һәйкәлдәй хис-тойгысыз күзәтүе, фани теләкләргә ияреп тимер капкаларны йодрык белән җимерергә, үзе кереп ятачак кабер чокырыннан куркып качарга маташуы, тормышын матди ихтыяҗларын гына кайгыртып уздыруы кешелек дәрәҗәсенә һәм абруена никадәр туры килә соң?

Галәм китабының төп асылы, башлангычы һәм барлык илаһи исем-сыйфатларның чагылышы булган кешенең бу тәртипкә салынган дөньядагы урыны, рухи һәм дини ризык белән тукланып, яратылышның иң югары дәрәҗәдәге рухи үзәге, камил нөсхәсе булуда түгелмени? Тормыш базарының иң төп кием е булган кәфен бөтен фани алыш-бирешләрдән, элемтәләрдән баш тарту ноктасы түгелмени?

Җәйге болыт рәвешендә узып барган дөнья тормышы ахирәт өчен борчылып алып барылмаса, бу якты көннәр караңгы төннәрсез генә була, дип уйлауга тиң.

Хак Тәгалә әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّ وَعْدَ اللَّهِ حَقٌّ فَلَا تَغُرَّنَّكُمُ الْحَيَاةُ الدُّنْيَا وَلَا يَغُرَّنَّكُمْ بِاللَّهِ الْغَرُورُ

**«И, кешеләр! Һичшиксез, Аллаһның вәгъдәсе бер хак. Дөнья тормышы сине алдамасын. Алдакчы булган (шайтан) да сезне Аллаһ (ярлыкавы) белән алдамасын!»** («Фатыйр», 5).

Кеше үзенә һәм галәмдәге тәртипкә гыйбрәт күзе белән караган очракта, дөнья тормышын ничек уздырырга тиешлеге турында уйланырга мәҗбүр булачак. Олуг максатлар белән яшәргә ниятләгән һәр кеше үз гомерендә иң күбе аны көткән үлем белән кызыксына. Ул хушлашу кеше өчен бик зур гыйбрәт чыганагы. Дөнья тормышында бары туфрактан ясалган ит-сөяктән гыйбарәт тәнен генә кайгыртканнар, ягъни нәфес тарафын үстереп, рухи якны көчсезләндергәннәр өчен «үлем» нинди куркыныч ахыр, соң мизгел булачак!

Алар дөньяда бәхет дип уйлаган фәкыйрьлекләренең фаҗигале чын йөзен үлемнән соң киләчәк кабат терелүгә төшенәчәк. Җәнабел-Хак әйтә:

إِذَا السَّمَاءُ انْفَطَرَتْ وَإِذَا الْكَوَاكِبُ انْتَثَرَتْ وَإِذَا الْبِحَارُ فُجِّرَتْ
وَإِذَا الْقُبُورُ بُعْثِرَتْ عَلِمَتْ نَفْسٌ مَا قَدَّمَتْ وَأَخَّرَتْ

**«Күк ярылгач. Йолдызлар коелгач. Диңгезләр ташыгач. Каберләр асты өскә әйләнгәч. Һәрбер җан киләчәккә ни әзерләгәнен һәм үзеннән соң (эшли алмыйча) калдырган һәрнәрсәне беләчәк!»** («әл-Инфитар», 1–5).

Мәхшәрдәге халык дөньяда яшәп калган вакытларын, ахирәт галәменең мәңгелеге һәм чиксезлеге белән чагыштырып, түбәндәгечә бәяләрләр:

كَأَنَّهُمْ يَوْمَ يَرَوْنَهَا لَمْ يَلْبَثُوا إِلَّا عَشِيَّةً أَوْ ضُحَاهَا

**«Алар аны күрәсе (кыямәт) көнне (дөньяда) үзләрен бер төштән соң (ахшам вакыты) яки төшкә кадәр генә торган дип санарлар»** («ән-Нәзигать», 46).

Шуңа күрә дә Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дөнья тормышын бәяләгән бер хәдис-шәрифендә*: «Дөнья миңа нигә кирәк?.. Минем хәлем дөньяда бер агач күләгәсендә утырып алган, аннары урынын калдырып киткән атлы юлчыга охшаган»*, – дип әйткән (Ибне Маҗә, «Зүһд», 3; Ибне Ханбәл, I, 391).

Җәнабел-Хак чын акыл ияләренең үзенчәлеген түбәндәге аяти кәримәдә шулкадәр анык, күркәм бәян кыла:

إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ لَآيَاتٍ لِأُولِي الْأَلْبَابِ
الَّذِينَ يَذْكُرُونَ اللَّهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَىٰ جُنُوبِهِمْ وَيَتَفَكَّرُونَ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ
وَالْأَرْضِ رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَٰذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

**«Алар (камил мөэминнәр) аякта торганда да, утырган килеш тә, янтыкларында килеш тә (һәрвакыт) Аллаһны зикер итәләр һәм күкләр белән җирнең яратылышы турында (тирән) фикерлиләр: “И, Раббыбыз! Син моны юкка яралтмадың. Син пакьсең! Безне Ут газабыннан сакла!”»** («Әли Гыймран», 191).

Бөтен җиһан бик төгәл тәртип белән корылган. Һәрнәрсәдә нәфис тигезлек кануны чагылыш таба. Күкләр һәм җир – төрледән-төрле күренеш-вакыйгаларда күзгә ташлана торган тиңсез тәртип үрнәге ул. Ай белән Кояш билгеле бер тәртиптә чыга һәм бата, болытлар тәртип белән хәрәкәт итә, яңгырлар бер үлчәмдә туфракка тамчылар коя, җир йөзенең язы һәм көзе, чәчәкләре, үләннәре бик төгәл бер тәртип белән барлыкка килә, ризыклар билгеле бер күләмдә һәртөрле мәхлукларга аерым-аерым әзерләнә. Шул рәвешле бөтен дөнья илаһи тәртип һәм үлчәмдә яшәгәндә, галәмнең иң өстен мәхлугы, мәхлукларның иң зиннәтлесе, иң камил сәнгать әсәре булган кешенең тәртипсез, чик-чамасыз, хис-тойгысыз һәм мәгънәсез тормыш алып баруын дөрес дип күз алдына китерергә мөмкинме соң?

Тормыш сынавын тапшыру өчен яралтылган бәндә акыл, хис-тойгы һәм тән-гәүдәгә кагылышлы балансны сакларга тиеш.

Кешенең:

Акыл балансы – гаҗәпкә калдырмый, шаккатырмый торган мәгълүматларга, хакыйкать нурларына;

Хисләр балансы, ягъни йөрәк гармониясе, күркәм әхлакка һәм сәламәт йөрәккә;

Бәдән-гәүдә балансы исә Хак Тәгаләгә коллык юнәлешендәге гамәли кыйммәтләргә таяна, боларның бөтенесенең иң күркәм, фазыйләтле чыганагы – Коръәни-Кәрим һәм Пәйгамбәребез сөннәте.

Кыскасы, мәхлукларның иң хөрмәтлесе булган кеше, иман һәм изге гамәлләр белән үз дәрәҗәсен күтәреп, дөньядагы илаһи аһәң составына керергә бурычлы. Аяти кәримәдә кеше, Коръән һәм дөнья төзелешендәге тәртипнең төгәллеге һәм сизгерлеге турында болай диелә:

الرَّحْمٰنُ عَلَّمَ الْقُرْآنَ خَلَقَ الْإِنْسَانَ عَلَّمَهُ الْبَيَانَ الشَّمْسُ وَالْقَمَرُ بِحُسْبَانٍ وَالنَّجْمُ وَالشَّجَرُ يَسْجُدَانِ وَالسَّمَاءَ رَفَعَهَا وَوَضَعَ الْمِيزَانَ أَلَّا تَطْغَوْا فِي الْمِيزَانِ وَأَقِيمُوا الْوَزْنَ بِالْقِسْطِ وَلَا تُخْسِرُوا الْمِيزَانَ

**«Рахман (булган Аллаһ) Коръәнне өйрәтте. Кешене яралтты. Аны аңлатырга өйрәтте. Кояш һәм ай бер хисап белән (хәрәкәт итә). Үләннәр һәм агачлар сәҗдә кылалар. Ул (Аллаһ) Күкне югары итте һәм мизанны урнаштырды. Мизанны бозмавыгыз өчен. Үлчәүне гадел итеп тотыгыз һәм (дөнья һәм ахирәттә) авырлыкны киметмәгез!»** («әр-Рахман», 1–9).

Йә Раббы! Бу галәмдә безне хикмәт һәм серләр хәзинәсе булган изге колларың белән бергә кыл! Безне мәхшәр көнне дә алар белән кубар!..

Амин!..


ХӘЗРӘТИ
ӘЙЮБ
галәйһиссәләм

*Тирән уй-фикерләр һәм сабырлык асылташы*

# ХӘЗРӘТИ ӘЙЮБ

*галәйһис-сәләәм*

Ягъкуб галәйһис-сәләәмнең игезәк кардәше Гыйс нәселеннән килгән пәйгамбәр. Димәшкъ тирәсендә яши. Аңа бик аз санда кешеләр иман китерә. Бабасы Хәзрәти Исхак галәйһис-сәләәм догасының бәрәкәте белән Аллаһ Тәгалә Әйюб галәйһис-сәләәмгә мул мал-мөлкәт, күп балалар бирә. Әйюб галәйһис-сәләәмнең хезмәтчеләре, басу-кырлары һәм мал-туары күп була. Фәкыйрьләргә, ятимнәргә, толларга бик еш ярдәм күрсәтә, табынында берәр фәкыйрь булмыйча торып, ашарга утырмый, Аллаһ аңа биргән нигъмәтләрне кунак сыйлау мөмкинлеге өчен ярата.

Гомеренең башлангыч чорында бай яши, урта яшьләрдә чакта фәкыйрь була, ватаныннан аерыла; гомер соңында исә Аллаһка шөкер кылып яшәве һәм дастаннарга керерлек сабырлыгы нәтиҗәсендә, кабат илаһи рәхмәткә тиенә. Җәнабел-Хак аның сабыр түземлеген түбәндәгечә мактап телгә ала:

إِنَّا وَجَدْنَاهُ صَابِرًا نِعْمَ الْعَبْدُ إِنَّهُ أَوَّابٌ

**«...Һичшиксез, Без аны (Әйюбне) сабыр итүче (риза хәлдәге) буларак таптык. Нинди күркәм бер кол иде! Һичшиксез, ул күп тәүбә кылучы иде»** («Сад», 44).

Әйюб галәйһис-сәләәм Димәшкъ тирәсендә яшәгән кешеләр өчен пәйгамбәр вазифасын башкара. Коръәни-Кәримдә аның илаһи вәхигә лаек булган пәйгамбәр икәнлеге хәбәр ителә:

إِنَّا أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ كَمَا أَوْحَيْنَا إِلَىٰ نُوحٍ وَالنَّبِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ وَأَوْحَيْنَا إِلَىٰ إِبْرَاهِيمَ
وَإِسْمَاعِيلَ وَإِسْحَاقَ وَيَعْقُوبَ وَالْأَسْبَاطِ وَعِيسَىٰ وَأَيُّوبَ وَيُونُسَ وَهَارُونَ وَسُلَيْمَانَ

**«(Хәбибем!) Һичшиксез, Без, Нухка һәм аңардан соңгы пәйгамбәрләргә вәхи җибәргән кебек, сиңа да вәхи иттек. Без Ибраһимгә, Исмәгыйльгә, Исхакка, Ягъкубка, аларның оныкларына, Гайсәгә, Әйюбкә, Юныска, Һарунга һәм Сөләйманга вәхи иттек…»** («ән-Ниса», 163).

وَوَهَبْنَا لَهُ إِسْحَاقَ وَيَعْقُوبَ كُلًّا هَدَيْنَا وَنُوحًا هَدَيْنَا مِنْ قَبْلُ وَمِنْ ذُرِّيَّتِهِ دَاوُودَ
وَسُلَيْمَانَ وَأَيُّوبَ وَيُوسُفَ وَمُوسَىٰ وَهَارُونَ وَكَذَٰلِكَ نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ

**«...Аннан алда да Нухны һидәят иткән идек. Аның нәселеннән Давытны, Сөләйманны, Әйюбне, Йосыфны, Мусаны һәм Һарунны да. Игелек кылучыларга әнә шулай әҗерләрен бирәбез»** («әл-Әнгам», 84).

**Сынау, сабырлык һәм әҗер-савап**

Әйюб галәйһис-сәләамнең мул мал-мөлкәте, балалары һәм ул ирешкән бөтен нигъмәтләр, илаһи сынау буларак, бер-бер артлы аннан тартып алына. Шуннан соң ул авыр чиргә дучар ителә. Ләкин Хак Тәгаләгә буйсынучанлыгы һәм Аңа тәвәккәл кылуы нәтиҗәсендә, тәненә, малына һәм балаларына килгән авырлыклар, казалар каршында бик зур сабырлык күрсәтеп, үзенең илаһи тәкъдиргә ризалыгын белдерә. Аның телдән-телгә мактап сөйләнгән сабырлыгы һәм Аллаһка буйсынучанлыгы кешелек тарихы сәхифәләренә гыйбрәт үрнәге буларак язылып куелды.

Әйюб галәйһис-сәләам кичкән сынау аның пәйгамбәрлек чорына туры килә. Башына төшкән һәртөрле бәла-казалар шайтан мәлгунь белән бәйле. Аның фазыйләтенә, күркәм холкына көнләшүдән түзеп тора алмагач, иблис, кеше рәвешенә кереп, халык арасында: «Шулкадәр нигъмәт һәм муллык эчендә яшәгәндә, гыйбадәттә тормыш кичерү җиңел ул. Әйюбне берәр кытлык һәм бәла вакытында күрергә кирәк!..» – дип коткы тарата һәм һәрвакыт аның дәрәҗәсен төшерергә маташа. Шуннан соң Әйюб галәйһис-сәләам Аңа гына буйсынганлыгын һәм Аңа гына тәвәккәл кылуын күрсәтсен өчен, Аллаһ Тәгалә әлеге сөекле пәйгамбәренә төрле бәла-казалар җибәрә.

Әйюб галәйһис-сәләамне сынарга ниятләгәч, беренче эш итеп, Җәнабел-Хак, аның малларын тартып ала. Бер сәл ташкыны белән – сарыкларын, җил-давыл белән игеннәрен харап итә. Көтүче кыяфәтенә кереп, шайтан Хәзрәти Әйюб янына чаба һәм кулына килгән форсатны файдаланып калырга тырыша. Шайтан, елый-елый, аңа күңелсез хәбәрне җиткерә: «И, Әйюб! Бик зур бәла килеп чыкты. Аллаһ Тәгалә синең бөтен мал-мөлкәтеңне юк итте бит».

Әлеге хәбәрне ишеткәч һич кайгыга төшмәгән Хәзрәти Әйюб, олуг буйсынучанлык һәм тынлык саклап, Раббысына мактаулар әйтә һәм кеше кыяфәтенә кереп килгән шайтанга: «Мал-мөлкәтне миңа Раббым биргән иде. Хәзер инде кире алды. Бердәнбер хуҗа Ул гына! Теләсә – бирә, теләсә – ала!..» – ди. Бу сүзләр, мондый мөнәсәбәт шайтанның ниятләрен пыран-заран китерә.

Соңрак исә, дәрес вакытында җир тетрәү нәтиҗәсендә, Әйюб галәйһис-сәләамнең балалары вафат була. Шайтан бу юлы да, кычкырып елый-елый, Хәзрәти Әйюб янына ашыга. Аллаһка каршы сүз әйттерер өчен, күзләреннән елгадай яшьләр агызып: «И, Әйюб! Аллаһ Тәгалә бер зилзилә белән өеңне җимерде. Бөтен балаларыңны тартып алды. Аларның интегеп кычкыру-ыңгырашуларына түзеп торырлык түгел иде. Ә син һаман монда басып торасың?»

– дип, вакыйганы шулкадәр кызганыч итеп тасвирлап бирә, Хәзрәти Әйюбнең илаһи тәвәккәллек һәм Аллаһка буйсынучанлык белән сугарылган йөрәгендәге мәрхәмәт хисе ташып чыгып, мөбарәк күзләреннән яшьләр тама. Ләкин ул, бу сынау каршында да бик зур сабырлык күрсәтеп, илаһи күренешкә ризалыгын белдерә.

Янә максатына ирешә алмаган шайтан ачудан кабара. Тагын нәрсәләрдер әйтергә җыенган чакта, Хәзрәти Әйюб аңа: «Әй, мәлгунь! Син – иблис бит, мине Раббыма каршы баш күтәрергә котыртасың! Балаларымның бер әманәт икәнен беләсең бит. Аларны хуҗасы кире алды. Бирүче дә Ул, алучы да Ул, ник рәнҗим? Мин һәр очракта да Раббыма мактаулар әйтүче колмын!» – дип белдерә.

Изге бәндәләрнең Хак Тәгаләгә буйсынуын, тәвәккәл кылуын Газиз Мәхмүт Һүдайи Хәзрәтләре бер шигырендә менә шулай матур шәкелдә телгә ала:

«Алучы да Син, бирүче дә Син, кылучы да Син;

Ни бирсәң, шул булыр, башка нәрсәбез бар соң!..»

Әнәс ибне Малик радыйаллаһу ганһе бәян кылганнардан:

«(Үги атам) Әбү Тальхәнең бер улы үлә. Бу вакытта ул кайдадыр тышта була. Хатыны Өмме Сүләйм, улының үлгәнлеген күргәч, аны юып кәфенли дә өйнең бер ягына урнаштыра. Шулчакта Әбү Тальхә кайтып керә һәм:

“Баланың хәле ничек?” – дип сорый. Хатыны: “Тынычланды, мин аның ял итүенә өметләнәм!” – дип җавап бирә.

Иртән ире Әбү Тальхә госел коенып, чыгып китәргә җыенганда, хатыны аңа баланың вафат булганын хәбәр итә. (Бик тәэсирләнеп, өеннән чыгып киткән) Әбү Тальхә, (шундук) Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына юл тота һәм аның белән бергә намаз укый. Аннары Пәйгамбәр галәйһис-сәләәмгә булган хәлне сөйләп бирә. Шуннан соң Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: *“Аллаһ Тәгалә бу төнегезне сезнең өчен бәрәкәтле кылгандыр дип өметләнәм”*, – дип әйтә» (Бохари, «Җәнаиз», 42, «Әдәб», 116).

Әнәс ибне Малик Хәзрәтләре бәян кылган бу вакыйга Өмме Сүләймнең зирәклеген, тәкъвалыгын һәм, аерым алганда, Җәнабел-Хакка бирелгәнлеген күрсәтә. Әлеге вакыйга әти-әни, бала, мал-мөлкәт кебек бөтен нәрсәләрнең бары әманәт кенә икәнлеген һәм хуҗасының кирәк вакытта аларны кире алганлыгын шулкадәр күркәм ачып бирә. Әйтерсең, Өмме Сүләйм Әбү Тальхәгә үз-үзен тотышы белән: «Балабыз аны безгә җибәргән Кодрәт иясе тарафыннан кире чакыртып алынды. Күпмедер вакыттан соң аның белән кыяматтә кабат очрашачакбыз. Кайгырма һәм зарланып тавышланма! Хак Тәгаләдән риза бул...» – дип әйтә.

Җәнабел-Хак Өмме Сүләймгә бик тиздән тупырдап торган матур бер угыл бүләк итә. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңа Габдуллаһ дип исем куша.

Иң ахырда Аллаһ Тәгалә Әйюб галәйһис-сәләамгә Коръәни-Кәримдә исеме белгертелмәгән бер авыру[160] җибәрә. Авыру шулкадәр көчәя ки, аның янына һичкем кермәслек дәрәҗәгә җитә. Бары шәфкатьлелек үрнәге булган хатыны Рахмә (Рәхимә) генә, тиңсез тугрылык һәм мәхәббәт үрнәге күрсәтеп, аңа хезмәт итүен, тәрбияләвен дәвам итә. Рахмә хатын кул хезмәте белән тормышны алып барырга тырыша, һәртөрле эшне дә яратып башкара.

Әйюб галәйһис-сәләәм шушы авыр чирле хәлендә дә зарланмый. Ул, Раббысына сыенып, хәмед-сәнәләрен дәвам итә. Пәйгамбәрләргә хас әдәплелек күрсәтеп, үзенең авыруын һәм хәлсезлеген шайтанга бәйләп карый. Бу хакта аяти кәримәдә болай дип хәбәр ителә:

وَاذْكُرْ عَبْدَنَا أَيُّوبَ إِذْ نَادَىٰ رَبَّهُ أَنِّي مَسَّنِيَ الشَّيْطَانُ بِنُصْبٍ وَعَذَابٍ

**«(Рәсүлем!) Әйюб колыбызны да искә ал. Менә ул: “Һичшиксез, шайтан миңа авырлык һәм мәшәкать белән кагылды”, – дип, Раббысына дога кылды»** («Сад», 41).

Чөнки шайтан, Әйюб галәйһис-сәләәмнең матур яшәвенә, күркәм хәленә көнләшеп, аңа зыян салырга тели, ләкин Әйюб галәйһис-сәләәм һәрнәрсәнең Аллаһтан икәнлеген аңлый, Аңа гына тәвәккәл кыла, үзен Аңа гына багышлый. Әйюб галәйһис-сәләәмне шөкердән, хәмед-сәнәдән һәм Аллаһтан риза булып яшәүдән ерагайту өчен бөтен тырышлыгы бушка киткән шайтан бу юлы шәһәр халкын котырта башлый: «Сак булыгыз, Рахмә белән очрашып, аңа ярдәм итә күрмәгез! Югыйсә Әйюбнең чире сезгә дә йогар! Хәзер үк аны шәһәрегездән куыгыз!»

Кала кешеләре бу котыртуга колак салып: «Әйюб белән бергә моннан чыгып китегез! Югыйсә сезне таш ыргытып үтерербез!» – дип, Рахмәгә яныйлар.

Рахмә хатын бичара хәлдә, Хәзрәти Әйюбне аркасына күтәреп, шәһәрне ташлап китә. Кала читендәге бер җиргә урнашалар. Әйюб галәйһис-сәләәмнең астына ком җәеп, баш тирәсенә таштан мендәр куя. Аннары кечкенә алачык корып, пәйгамбәргә тугры хезмәтен дәвам итә. Аллаһның сабыр пәйгамбәре Хәзрәти Әйюб хәтта шушы авыр хәлендә дә шул тирәдән узып йөрүчеләрне яхшылыкка өндәү, яманнан тыелырга чакыру белән шөгыльләнә.

Тормышларын алып барыр өчен, хатыны Рахмә шәһәрдәге хатын-кызлар өчен бау үрә. Бервакыт ул иренә: «Син бит пәйгамбәр! Аллаһ Тәгаләдән сихәт

160. Коръәни-Кәримдә нинди авыру икәнлеге әйтелми, чөнки монда авыру турында түгел, ә Әйюб галәйһис-сәләәмнең сабырлыгы һәм һәрвакыт Аллаһтан ризалыгы турында аңлату төп максат булып тора.

һәм гафу сорасаң иде дә, бу авырлыкларны синнән алса иде!» – дигәч, Әйюб галәйһис-сәләәм: «Сау-сәламәт хәлдә күпме яшәдек?» – дип сорый. Рахмә хатын: «Сиксән ел иде», – дип җавап бирә. Шуннан соң Хәзрәти Әйюб: «И, Рахмә! Авырлык һәм бәлаләр чоры саулык һәм рәхәтлек вакыты кадәр булмыйча торып, Җәнабел-Хакка зарланырга оялам. Аллаһ Тәгалә безгә нигъмәтләр биргәндә (риза булабыз да), Аннан килгән бәлаләргә ничек сабыр итмәскә тиешбез?!» – дип белдерә.

Хәзрәти Әйюбнең мондый шаккаткыч сабырлыгы, аяти кәримәдә макталган кебек, хәдис-шәрифтә дә хөрмәт белән телгә алына: *«Хәзрәти Әйюб, кешеләрнең иң йомшак холыклысы, иң сабыры һәм үз ачуын иң күп җиңгәне иде»* (Ибне Әби Шәйбә, «Мусаннәф», III, 201).

Аның Хак Тәгаләдән ризалыгы тулы, һич китек-кимчелексез була. Түбәндәге шигырь юллары аның олуг сабырлыгын һәм Аллаһка бирелгәнлеген чагылдыра:

«Хуш миңа Синнән килгәннәр,

Әле ачылмаган чәчәк йә энә булса да,

Зиннәтле җилән яки кәфен булса да.

Утың да хуш, нурың да хуш!..»

Әйюб галәйһис-сәләәм күңеленә вәсвәсә сала алмаган шайтан бу юлында аның хатыны Рахмәгә бәйләнә. Адым саен аның каршына чыгып, зиһенен чуалтырга маташа. Рахмә хатын исә бу хакта Хәзрәти Әйюбкә җиткереп бара. Әйюб галәйһис-сәләәм исә хатынына: «И, Рахмә! Синең юлыңа иблис чыга ул. Игътибарлы бул, сиңа вәсвәсә салып, миннән аерырга тели!..» – дип кисәтеп куя.

Рахмә хатын Йосыф галәйһис-сәләәмнең оныкларыннан була. Ул бабасы Йосыфтан бер өлеш чибәрлекне мирас итеп ала. Тирә-ягында Рахмәдән матуррак һичкем булмый. Шунлыктан шайтан, беркөнне аның каршына бик матур бер ир-егет кыяфәтендә чыгып, сүзката: «Синнән гүзәлрәк һичкемне күргәнем юк. Мин шушындагы якын бер авылдан. Байлыгымның да хисабы-саны юк...» Раббысына сыенып, Рахмә: «Мин авыру Әйюб пәйгамбәрнең хатыны. Аңа хезмәт итәм. Һәм мин әлеге хөрмәтле пәйгамбәрдән башка берәүгә һич күңел бирмәм...» – дип китеп бара. Рахмә ире янына кайткач, вакыйганы сөйләп бирә. Бу хәлне ишеткәч, Хәзрәти Әйюб бик ярсый һәм ачу белән: «И, Рахмә! Мин сине кисәтеп куйдым бит. Әгәр савыксам, сиңа йөз тапкыр таяк белән сугачакмын!» – дип ант итә.

Әйюб галәйһис-сәләәмнең авыруы көннән-көн көчәя. Бу хәле аның пәйгамбәрлек вазифасын башкаруына комачаулый башлый. Ул, догага кулларын күтәреп, Бөек Затка мөрәҗәгать итә.

أَنِّي مَسَّنِيَ الضُّرُّ وَأَنْتَ أَرْحَمُ الرَّاحِمِينَ

**«...Һичшиксез, миңа бер зарар кагылды. Син исә мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесесең!»** – дип («әл-Әнбия», 83), ул илаһи мәрхәмәт аша шифа табар өчен, күңеле белән Җәнабел-Хакка юнәлә.

Әйюб галәйһис-сәләамнең шушы рәвешле дога кылуының сәбәбе мәсьәләсендә тәфсирләрдә төрле риваятьләр китерелә.

Имам Җәгъфәр әс-Садыйк Хәзрәтләре болай ди: «Кыенлык чоры шактый сузылгач, шайтан: "И, Әйюб! Чирдән котылырга теләсәң, миңа сәҗдә кыл!" – дип тәкъдим итә. Хәзрәти Әйюбнең йөрәген кайгы-борчу биләп ала һәм ул: "Чирдән түгел, ач күзле дошманның саклап торуыннан интегәм", – дип, Раббысына догада: "Миңа бер зарар кагылды", – дип әйтә».

Башка бер риваять. Хәзрәти Әйюбкә иман китергән берничә кеше: «Әгәр ул хәерле зат булса, мондый авыр бәлагә дучар ителмәс!» – дип сөйләнә башлый. Наданнарның бу сүзләре Хәзрәти Әйюбне бик рәнҗетә. Янә бер риваятьтә чарасыз калган Рахмә хатынның, ризык сатып алу өчен, кием-салымын сатып җибәрүе әйтелә. Әйюб галәйһис-сәләам, моны белеп алгач, бик пошаманга төшә һәм Раббысына ялвара. Тагын бер риваять. Хәзрәти Әйюб янына килеп, Җәбраил галәйһис-сәләам: «Хак Тәгалә хәзинәсендә сынау өчен бәла-казалар күп. Аларга түзеп тора алмаячаксың. Син Аллаһтан саулык сора!» – дип, шифа табар өчен, Җәнабел-Хакка дога кылырга киңәш бирә.

Риваятькә күрә, берәү Рәсүлуллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм мәчетенә керә дә Әйюб галәйһис-сәләам белән бәйле сораулар бирә. Хәзрәти Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез елап җибәрә һәм болай ди: *«Аллаһ Тәгалә белән ант итәм, Әйюб бәладән зарланмады, ыңгырашмады. Ләкин җиде ел, җиде ай, җиде көн, җиде төн авыр хәлдә калды. Аягына басып, намаз укырга теләде, тик тора алмады, егылды. Хак Тәгаләгә хезмәтендә кимчелек тойгач: "Һичшиксез, миңа бер зарар кагылды", – дип әйтте»*[161].

Хәзрәти Әйюбнең сүзләре беренче карашка сызлану, ыңгырашу кебек тоелса да, чынлыкта бер дога була, чөнки сызлану, ыңгырашу, дигәндә, кешеләргә зарлану күздә тотыла. Аллаһ Тәгаләгә мөрәҗәгать исә андый сызлану, шикаять түгел. Ягъкуб галәйһис-сәләам дә, улы Йосыф галәйһис-сәләамнән аерылу газабы һәм сагышы аркасында бик зур кайгы кичерә, аяти кәримәдә аның мондый сүзләре китерелә:

قَالَ إِنَّمَا أَشْكُو بَثِّي وَحُزْنِي إِلَى اللَّهِ وَأَعْلَمُ مِنَ اللَّهِ مَا لَا تَعْلَمُونَ

**«Ул әйтте: "Мин хәсрәтемне һәм борчуымны Аллаһка гына шикаять итәм. Һәм мин сез белмәгән нәрсәләрне (вәхи аша) Аллаһтан беләмен"»** («Юсуф», 86).

161. . Карагыз: Куртуби, «Тәфсир», XI, 323, 327.

**Авырудан котылу**

Рахмә хатын азык-төлек эзләргә чыгып китә. Шулвакыт Җәбраил галәйһис-сәләәм килеп, Җәнабел-Хактан: «И, Әйюб! Бәла-каза җибәрдем, сабыр иттең. Хәзер исә кабат саулык һәм нигъмәт бирәчәкмен!» – дигән хәбәр белән бергә мондый әмер алып килә:

ارْكُضْ بِرِجْلِكَ هَذَا مُغْتَسَلٌ بَارِدٌ وَشَرَابٌ

**«Аягың белән (җиргә) тип! Бу салкын су – коеныр һәм эчәр өчен!»** («Сад», 42).

Әйюб галәйһис-сәләәм илаһи әмердә кушылганча, аягы белән җиргә ора. Шундук бер чишмә бәреп чыга. Ул шушы су белән юына һәм, шулай итеп, бер могҗиза буларак, эчке һәм тышкы чирләреннән арына. Башка бер риваятькә күрә, Әйюб галәйһис-сәләәм җиргә типкәч, берсе җылы, икенчесе салкын булган ике чишмә бәреп чыга. Ул җылы су белән юына, салкынын эчә.

Аяти кәримәдә **«Аягың белән җиргә тип!»** дигән әмер аша хәтта могҗиза өчен дә бәндәнең көч, хезмәт, эш-гамәл башкарырга тиешлеге турында хәбәр җиткерелү игътибарга лаек. Димәк, бәндә утырып дога кылу белән генә канәгатьләнмичә, теге яки бу сәбәп, гамәл турында да онытмаска тиеш. Шулай ук доганың таләп-шартларын да үтәргә кирәк. Аятьтәге әмер Мәрьям кыйссасындагы **«Хөрмә агачы кәүсәсен үзеңә таба селкет!..»** – дигән әмергә охшаган («Мәрьям», 25). Шулай ук:

إِلَيْهِ يَصْعَدُ الْكَلِمُ الطَّيِّبُ وَالْعَمَلُ الصَّالِحُ يَرْفَعُهُ

**«…Күркәм сүзләр Аңа ирешә. Изге гамәл исә, аны (Аллаһка) ул күтәрә!»** («Фатыйр», 10) дигән аятьне хәтерләтә.

Әйюб галәйһис-сәләәмнең олуг хөрмәт һәм әдәп белән Җәнабел-Хакка юнәлүе нәтиҗәсендә догасы кабул була һәм аңа шифа, рәхмәт, илаһи мәрхәмәт ишекләре ачыла. Аяти кәримә бу хакта:

فَاسْتَجَبْنَا لَهُ فَكَشَفْنَا مَا بِهِ مِنْ ضُرٍّ وَآتَيْنَاهُ أَهْلَهُ وَمِثْلَهُمْ مَعَهُمْ رَحْمَةً مِنْ عِنْدِنَا وَذِكْرَىٰ لِلْعَابِدِينَ

**«Без (догасын кабул итеп) аңа җавап бирдек һәм аңа килгән зарарны китәрдек. Хозурыбыздан бер рәхмәт һәм гыйбадәт кылучыларга бер үгет булсын дип, аңа гаиләсен һәм янында булган кадәрен биргән идек»**, – дип хәбәр ителә («әл-Әнбия», 84).

Хәзрәти Җәбраил сәламәтлеге кире кайтарылган Әйюб галәйһис-сәләәмнең башына, Аллаһның әмере белән, бер таҗ куя, матур киемнәр кидерә. Илаһи рәхмәт болыты килеп, Хәзрәти Әйюб өстенә алтын бөртекләре

яудыра. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу вакыйганы болай бәян кыла:

*«Могҗизалы суда юынган арада, Әйюбнең алдына бер көтү алтын чикерткә төшә. Әйюб аларны шундук җыеп, кесәсенә тутыра башлый. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә: "Әй, Әйюб! Күрәсең, Мин, малыңны сиңа кире кайтару шарты белән, сине баетмадыммы?" – диде. Хәзрәти Әйюб: "Әйе, йә, Раббы! Мине шул рәвештә бай иттең. Ләкин Синең хәер һәм бәрәкәт казнасына ихтыяҗсыз яши алмыйм. Шул сәбәпле Синең катыңнан ни җибәрелсә дә, кабул итәм, чөнки бирүче – Син, ничек инде мин Син биргән нәрсәне кире кагыйм?!" – диде»* (Бохари, «Госел», 20, «Әнбия», 20; Нәсаи, «Госел», 7).

Шулвакытта Рахмә хатын шәһәрдән кайтып керә һәм Хәзрәти Әйюбне танымый. Аны югалган дип уйлап, сахрага чыгып йөгерә һәм кычкырып елый башлый. Әйюб галәйһис-сәләәм аңа дәшә: «Әй, ханым! Кемне эзлисең?» «Бер хаста кешем бар иде, тормыш иптәшем иде. Шулкадәр авырлык кичердек тә, хәзер ул хәзинәне югалттым...» «Ул нindирәк кеше иде?» «Сабыр Әйюб иде ул. Сау-сәламәт чагында сиңа охшаган иде» «И, Рахмә! Менә мин ул. Аллаһ Тәгалә миңа саулыгымны кайтарды». Икесе дә сөенечтән елашып, Җәнабел-Хакка шөкер кылдылар.

Әйюб галәйһис-сәләәм әүвәлге яшь һәм көчле чагына кайта. Моңа өстәп, Аллаһ Тәгалә аңа әүвәлгедән дә күбрәк мал-мөлкәт һәм бала бүләк итә:

وَوَهَبْنَا لَهُ أَهْلَهُ وَمِثْلَهُمْ مَعَهُمْ رَحْمَةً مِنَّا وَذِكْرَىٰ لِأُولِي الْأَلْبَابِ

**«Бездән бер рәхмәт һәм аек акылга ия кешеләр өчен бер үгет булсын өчен, Без аңа гаиләсен һәм алар белән бергә булган кадәр бирдек»** («Сад», 43).

Әйюб галәйһис-сәләәм һәм аның таркау хәлдә яшәгән гаиләсе, ниһаять, кабат бергә берләшә һәм элеккедән дә зуррак илаһи нигъмәтләргә лаек була.

Авырудан соң саулыкка ирешкән тәүге төннең таңында Хәзрәти Әйюб галәйһис-сәләәм «аһ!» дип ихлас ыңгырашып куя. Моның сәбәбен сорагач, ул: «Һәр төн сәхәр вакытында: "Әй, авыру кешебез, хәлең ничек?" – дигән тавыш ишетә идем. Хәзер янә шул вакыт җитте, тик: "Әй, безнең сау колыбыз, хәлең ничек?" – дигән авазны ишетмәдем. Шуңа күрә елыйм», – дип җавап бирә.

### Рахмә хатынның хезмәте өчен әҗере

Риваятькә күрә, хатынының бер хатасы аркасында Әйюб галәйһис-сәләәм, савыккач, аңа йөз таяк сугарга ант итә. Ләкин хатынның аңа күрсәткән хезмәте һәм фидакярлеге бик зур була. Шунлыктан Аллаһ Тәгалә, йөз данә иген саламыннан җыелган бер бәйләм белән бер тапкыр сугуны бу ант өчен кәффарәт икәнлеген белдереп, аларга мәрхәмәт белән мондый әмерен ирештерә:

وَخُذْ بِيَدِكَ ضِغْثًا فَاضْرِبْ بِهِ وَلَا تَحْنَثْ إِنَّا وَجَدْنَاهُ صَابِرًا نِعْمَ الْعَبْدُ إِنَّهُ أَوَّابٌ

**«Кулың белән бер бәйләм ал да шуның белән сук һәм антыңны бозма». Һичшиксез, Без аны (Әйюбне) сабыр итүче буларак таптык. Нинди күркәм бер кол иде! Һичшиксез, ул күп тәүбә кылучы иде»** («Сад», 44).

Аяти кәримәдәге җиңеллек, рөхсәт шәргый җәзалар һәм нәзерләрдә «Әйюб рөхсәте» исеме белән кереп кала. Аятьтә бу бәйләмнең ни бәйләме икәнлеге анык белдерелмәгәнгә күрә, башка мәгънәләрдә дә аңлатыла. Ягъни бу әмер андый рөхсәт, җиңеллеккә генә түгел, үз кул астыңа бер җәмәгать тупларга кирәклегенә дә ишарәли.

# РИЗАЛЫК

**«Һичшиксез, Без аны (Әйюбне) сабыр итүче (ризалык хәлендәге бер кол) буларак таптык. Нинди күркәм бер кол иде! Һичшиксез, ул күп тәүбә кылучы иде»** («Сад», 44).

Аллаһтан башка бөтен мәхлуклар, иң гадиеннән иң камиленә кадәр билгеле бер иерархиягә ярашлы рәвештә яралтылган. Бу иерархиянең иң югары ноктасында кеше тора, чөнки ул Раббының бөтен сыйфатларыннан үзенә өлеш алган һәм шунлыктан үзендә капма-каршылыкларны туплаган. Ягъни анда ике төрле һәм капма-каршы котыптагы сыйфатлар, гамәлләр булган игелек һәм явызлык, яхшылык һәм яманлыкка омтылыш урын алган. Аллаһ Тәгаләдә илаһи затка хас сыйфатта һәм тынычлык хәлендә булган капма-каршылыклар кешедә мәңгелек конфликт китереп чыгара.

Әгәр кеше үз ихтыярын уңай теләк омтылышларын үстерү юнәлешендә куллана алса, йөрәген пакьләү нәтиҗәсендә, үз шәхесендә хәерле, игелек сыйфатларның өстен чыгуын тәэмин итә алса, шул уңышларына нисбәтле рәвештә Раббысына якынаер. Моңа ирешкән күңелләр барыр җиренең ахырына җиткән мөһаҗир юлчылар кебек, әйтерсең, бик теләгән нәрсәне үзләштерү, бик көткән кешең белән кавышу бәхетен тояр. Шул рәвешле бәндә белән Аллаһ арасындагы ераклык кыскарып, тормышның «мөһаҗирлек, чит җирдә булу» кебек сыйфаты юкка чыга. Кеше аңындагы иң тирән һәм иң авыр газапларның чыганагы – Аллаһтан ерак булу аркасында килеп чыккан җәфа-изалар, хәтта беренче карашка шундый ук калган кебек күренсә дә, азая башлый. Хәтта бу газапларга өстәлгән бәндәчел авыртулар-сызланулар да Раббы белән бергә булу шатлыгы тәэсирендә сизелмәс-тоелмас бер хәлгә килер. Әйтерсең, дөньяви газап-интегүләр наркоз белән басылган кебек булыр.

Мондый яссылыкта газап-авыртулар Раббының бер игътибары, хөрмәте рәвешендә кабул ителеп, сөенечкә әйләнер. Җанны яулап алган бу шатлыкның колачы-киңлеге хәтта кайчак кешенең матди тарафы – бәдәненең физик халәтенә дә йогынты ясар. Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһенең балтырына кадалган укны Раббыга иң якын вакыт – намазда чакта тартып алуы моңа бик үтемле мисал булып тора.

Йөрәкне пакьләү һәм нәфесне тәрбияләү нәтиҗәсендә аң-зиһен югары дәрәҗәгә ирешкәч, алдавыч булган фани нәрсәләрнең тәэсиреннән котылып, Хак Тәгаләгә буйсыныр. Адәм баласы һәр күренеш-вакыйгада беренчел сәбәпкә барып тоташа торган сәбәпләр чылбыры барлыгын аңлый башлый һәм, аң-зиһен камиллегенә җиткәндә, һәр сәбәпне бар итүченең Аллаһ Тәгалә икәнлеген төшенер. Шулчакта бик зур шатлык-бәхеткә чумып:

«Хуш миңа Синнән килгәннәр,

Әле ачылмаган чәчәк йә энә булса да!» – дигән юллардагы рухый нәфислеккә ирешер. Бу халәткә күтәрелгән затларның, күңел күзләре ачылып, алар сәбәп һәм чараларга әһәмият бирми башлар, ә чын, ахыргы сәбәп иясе һәм төп сәнгатькярдә, ягъни Халикъ Тәгаләгә эреп кушылырга омтылырлар. Андый камиллеккә ирешмәгәннәр исә сәбәпләр чылбырындагы сәбәпләрнең берсендә тукталып кала. Ул сәбәпләр күңел өчен бер ятьмә булган караңгы төннәргә тиң һәм күп очракта алар Аллаһ белән кавышуга комачаулый.

Нәфес һәм дөнья теләк-омтылышларын басуга ирешкән шагыйрь Юныс Әмрә күңел баскычларын һәм үзенең Хак Тәгаләдә эреп югалуын бер шигырендә бик матур белдерә:

«Суфиларга кирәк сөхбәт,

Дусларга кирәк ахирәт,

Мәҗнүннәргә Ләйлә кирәк,

Миңа Син, Син кирәк!..»

Мондый камиллеккә ирешүнең иң күркәм чарасы төрле газапларга китергән илаһи сынаулардан гыйбарәт. Шуңа күрә, хәдис-шәрифтә дә расланганча, кешеләр арасында төрле җәфа-авырлыклар иң күбе пәйгамбәрләргә җибәрелә, чөнки алар үз өммәтләре өчен үрнәк булып тора. Вазифалары таләп иткәнчә, алар Раббыга иң якын халәттә булырга тиеш, бу якынлык исә сөйгәненә бәйлелек, якынлык дәрәҗәсенә нисбәтле газапларга нигезләнә. Чиктән тыш шатлану яки чиктән тыш газаплану кебек нәфес тозагы булып торган иң радикаль нокталарга бирелмичә, һәрдаим «ризалык» халәтендә гомер кичереп, шуның нәтиҗәсендә «сабырлык ияләре һәм Аллаһка тәвәккәл кылучылар» булганга, пәйгамбәрләрдә күз алдына китерә алмаслык түземлелек сыйфаты күзәтелә.

Әсхабе кирамнан Әбү Сәгыйд әл-Худри радыйаллаһу ганһе Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезне Ул авырган чакта зиярәт кыла һәм Аңа кичерергә туры килгән бик көчле авырту-сызлануларга шаһит була. Әбү Сәгыйд әл-Худри болай дип сөйли: «Кулымны Аллаһның Рәсүленең өстенә куйдым, кайнарлыгын юрган аркылы да сизә идем. “Йә, Рәсүлүллаһ, тәнегез бик кайнар!” – дидем. *“Без (пәйгамбәрләр) шундый. Бәлаләр безгә катлы-катлы килер, моңа каршы әҗерләре дә катлы-катлы бирелер”*, – дип белдерде.

“И, Аллаһның Рәсүле! Кешеләрдән кемнәр иң күп бәлагә дучар ителә?” – дип сорадым. *“Пәйгамбәрләр!”* – дип җавап бирде. ”Аннары кемнәр?” – дидем. *“Аннары изгеләр!”* – диде һәм әлеге аңлатмасына өстәп куйды: *“Алардан кайберләре шулкадәр фәкыйрьлеккә эләгер ки, үзен каплаган тупас киемнән кала бернәрсә дә таба алмас. Сез муллыкка сөенгән кебек, алар бәла-авырлыкка сөенерләр”*» (Ибне Мәҗә, «Фитән», 23).

Шуңа күрә күңелгә шатлык бирә торган күренешләр һәм вакыйгалар каршында ризалык күрсәтеп, авырту-газапларга кайгыру, зарлану асылда дөрес түгел. Ләкин йөрәген иң камил дәрәҗәдә пакьләмичә, тәрбияләмичә торып, кеше мондый бәндәчел кимчелектән җиңел генә котыла алмый. Хәзрәти Ягъкуб улы Хәзрәти Йосыфны югалту газабын, аны сагынуын күңел төпкеленә яшереп: «Миңа күркәм сабырлык күрсәтергә кала!» – дип әйтә алса да, ул моның өчен пәйгамбәрлек бәрабәренә үзенә насыйп ителгән гайре табигый камиллегенә, игелеклелегенә бурычлы була. Чыннан да Хәзрәти Ягъкуб үзенең күңелен Раббыдан кала һичкемгә ачмый. Шул рәвешле аның сагыш-хәсрәте нәтиҗәдә кавышу-очрашу белән төгәлләнә.

Риваятькә күрә, Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез Җәбраил галәйһис-сәләамнән: *«Ягъкубның Йосыфны сагынып кайгыруы нинди дәрәҗәгә җиткән иде?»* – дип сорый. Җәбраил галәйһис-сәләам: «Баласын югалткан җитмеш ананың барысының бергә сагыш-кайгысы кадәр дәрәҗәгә!» – дип җавап бирә. Шуннан соң Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез: *«Ул очракта моның савабы никадәр?»* – дигән сорау бирә. Җәбраил галәйһис-сәләам: «Йөз шәһидлек савабы, чөнки ул Аллаһ турында бер мизгелгә генә дә начар уйлап карамады», – дип белдерә (Суюти, «әл-Дүррүл-Мәнсур», IV, 570).

Димәк, кичергән кайгы-җәфалар, беренче карашка, тормышта сөенечкә, бәхеткә аркылы төшкән киртә булып тоелса да, чынлыкта алай түгел. Сабыр итү һәм Аллаһтан килгән сынау-бәлаләргә ризалык белдерү тиешлеген белүчеләр өчен андый авырлыклар тагын да зуррак сөенечләргә ирешү чарасы булып тора.

Хәзрәти Мәүләна бу хакта кыска һәм үтемле итеп әйтеп бирә:

«Кайгы кулы күңел ботагыннан саргайган яфракларны селкеп төшерер. Аның урынына тагын да нәфисрәк, яңарак шатлык яфраклары үсеп чыгар».

Кайгы, җәфа-газаплар нәфес теләкләрен зәгыйфьләтә һәм нәтиҗәдә кеше җанына, аны иң югары дәрәҗәгә күтәрәчәк йогынты ясый. Шуңа күрә кешеләргә юл күрсәтергә йөкләмә алган игелекле затлар мәҗбүри рәвештә иң зур газаплар аша уздырыла. Иза-җәфалар тулы хәят юлында иң күп җиңүгә китерә торган чара мәхәббәттән гыйбарәт. Шул сәбәпле шагыйрь Фузули болай дип язган:

«Йә Раббы, бәлане сөю белән таныт миңа,<br>
Бер сулышка да бәлане сөюдән аерма!»

Аллаһны ихлас яраткан әүлиялар күзлегеннән караганда, иза-җәфа белән шатлык сөенечләр игез туганнар санала. Алар мондый шатлыкларның һәм интегүләрнең ни өчен бирелгәнен яхшы белә. Шунлыктан һәрдаим Аллаһка ихлас буйсыну халәтендә яшиләр. Йөрәген әнә шундый хикмәтле сер эчендә сугарып үстергән Дәртле исемле шагыйрь кайгы-борчуын бик матур белдерә:

«Гыйшык утына янган ит кәбабы без,
Аерылу белән елаган күз тулы абыз,
Җимерек итеп ясалган йорт-җиребез,
Коллар булсак та, булмасак та, бер үк!»

Муса галәйһис-сәләамнең таягы каршында көчсез калган сихерчеләр: «Без Муса һәм Һарунның Раббысына сәҗдә кылабыз!» – дип белдерә. Фиргавен аларга бик көчле җәзалар белән яный: «Мин сезнең кулларыгызны һәм аякларыгызны чалыштырып чабып өзәчәкмен, шуннан соң сезне хөрмә кәүсәсенә кагып куячакмын! Үлемнең иң ачысын татыячаксыз!» Сихерчеләр исә моңа җавапта: «Синең гамәлең (безгә бирәчәк җәзаларың) безгә бер зыян да китермәс! Ни булса да, Раббыбызга кайтарылачакбыз!» – дип, ахмак Фиргавенгә дөньяви газапларның вакытлы, фани икәнлеген аңлаталар, шулай итеп аның янавына каршы чыгалар, чөнки олуг хакыйкатькә ирешүнең рухи сөенече, югарыда әйтелгәнчә, дөньяви иза-җәфаларны аң-зиһен өчен көчсезләндерә һәм әһәмиятсез нәрсәгә әйләндерә.

Башта үлүл-газыйм пәйгамбәр белән ярышка чыккан сихерчеләр бөек хакыйкатьне аңлагач, иман тәэсирендә бик дулкынланып, Муса галәйһис-сәләам нең пәйгамбәрлеген таныйлар. Шушы иман шатлыгы белән алар шәһидлек ширбәтен эчүгә өстенлек бирә. Дөньядагы җәзаларга каршы көрәшкә чыгып, илаһи мәңгелеккә таба сәфәргә кузгалалар. Шулай итеп, авыр җәза булып күренгән золым алар өчен мәңгелек бәхет чарасына әйләнә. Бу сихерчеләр Хак Тәгаләдән килгән каһәрне дә рәхмәт итеп кабул итә торган изге бәндәләргә әверелә.

Фиргавен исә, иблис кебек үз тәкәбберлегенә җиңелеп, ап-ачык хакыйкатьне инкяр итүдән туктамый. Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ үҗәтләнеп көферлеккә ябышкан кяферләрнең хәлен менә болай тасвирлый:

«Әгәр игътибар итсәң, һичбер кяфернең инкяры инкяр итү өчен генә түгел».

«Ә хөсетлеге аркасында дошманын җәфалар яки үзен күрсәтү өчен».

Тугры затлар өчен Хак Тәгаләнең газаплары бу вакытлы хыял һәм чагым дөньясының шатлыкларыннан, бәйрәмнәреннән мең тапкыр артыграк! Алар гавам илаһи рәхмәт дип юнәлгән нәрсәләрдән йөз чөерә. Хәзрәти Мәүләна күркәм бәянын дәвам итә:

«Гавам өчен тулысынча рәхмәт булган нәрсәләр – нәфис затлар, ягъни әүлиялар өчен бер бәла ул».

«Болар арасындагы аерманы аңлар өчен, халык бәла-казалар, кайгы-хәсрәтләр күрергә тиеш!»

Әүлиялар ирешкән ризалык дәрәҗәсен, ягъни Хак Тәгаләдә эреп югалу мәртәбәсен белдерә торган сүзне табып булмый, чөнки ул дәрәҗә моны бел-

мәгәннәр өчен билгесез серле күренешләр белән тулы аерым бер тойгыдан гыйбарәт.

Әйюб галәйһис-сәләәмнең авыруы бик көчәйгән көннәренең берендә Рахмә хатын иренә: «Син бит пәйгамбәр! Аллаһ Тәгаләдән сихәт һәм гафу сорасаң иде дә, бу авырлыклардан котылсаң иде!» – дигәч, Әйюб галәйһис-сәләәм : «Сау-сәламәт хәлдә күпме яшәдек?» – дип сорый. Рахмә хатын: «Сиксән ел иде», – дип җавап бирә. Шуннан соң Хәзрәти Әйюб: «И, Рахмә! Авырлык һәм бәлаләр чоры саулык һәм рәхәтлек вакыты кадәр булмыйча торып, Җәнабел-Хакка зарланырга оялам. Аллаһ Тәгалә безгә нигъмәтләр биргәндә (риза булабыз да), Аннан килгән бәлаләргә ничек сабыр итмәскә тиешбез?!» – дип белдерә.

Әйюб галәйһис-сәләәмнең үз-үзен шулай тотышы ризалыкның иң матур үрнәге булып тора. Авырган чакта, Әйюб галәйһис-сәләәм бөтен авырту-сызлауларга карамастан, үзенең хәле турында зарлану түбәнлегенә төшмичә, тәкъдиргә ризалык таләп иткән сабырлыгын күрсәтер өчен, чире турында хәтта Җәнабел-Хакка мөрәҗәгать итүдән, Аннан саулык-сәламәтлек сораудан да кыенсына. Ахыр чиктә хатыны бик үҗәтләнеп киңәш иткәч кенә, Аллаһка: **«Син мәрхәмәтлеләрнең иң Мәрхәмәтлесе!»** – дип догада ялвара. Бу догадан соң Аллаһ Тәгалә, даими гыйбадәттә яшәгән бәндәләргә бер рәхмәт мисалы буларак, Әйюб галәйһис-сәләәмнең кайгы-хәсрәтләрен бетереп, авыруына шифа бирә. Шулай итеп, сабырлык, шөкер итү, буйсынучанлык һәм Аллаһка мәхәббәт нәтиҗәсендә Әйюб галәйһис-сәләәм әүвәлге сәламәт, ныклы тормышы кире кайтарыла.

Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Әйюбне шушы бөтен вакыйгалар барышында һәрвакыт ризалык хәлендәге сабыр кол итеп күрүен аяти кәримәдә телгә ала. Әйюб галәйһис-сәләәмнең сабырлыгы һәм ризалык халәте Хак Тәгалә юлына баскан суфилар һәм дәрвишләр аеруча гыйбрәт алырга тиешле иң матур үрнәкне тәшкил итә.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Таифтә күргән иза-җәфалар башка һичбер бәндәгә насыйп булмаган «Мигъраҗ» вакыйгасының нигезенә салына.

Башка бер күренешкә бәйле рәвештә Хәлилуллаһ дәрәҗәсенә ирешкән Ибраһим галәйһис-сәләәмнең эш-гамәлләре дә Хак Тәгаләгә буйсынучанлык һәм бирелгәнлекнең башка төрле чагылышын күрсәтә.

Хәзрәти Ибраһим галәйһис-сәләәмне утка ташларга җыенган мизгелдә, Җәбраил галәйһис-сәләәм килеп, аннан: «Берәр теләгең бармы, миңа берәр үтенечең юкмы?» – дип сорый. Ибраһим галәйһис-сәләәм: «Әйе, бер үтенечем бар, ләкин сиңа түгел!» – дип җавап кайтара. Аннары Җәбраил галәйһис-сәләәмнән: «Утка яндыру сәләтен кем бирә?» – дип сорау бирә.

Нәтиҗәдә, Ибраһим галәйһис-сәләәмнең Аллаһка карата мәхәббәте дөнья утын бер мизгелдә гөлбакчага әйләндерә, чөнки Ибраһим галәйһис-сәләәм әйбер-күренешләрнең серләрен аңлый һәм ул Хак Тәгаләдә «эреп югала».

Хак Тәгаләне тануда Анда эреп югалу дәрәҗәсенә җиткәннәр өчен Аллаһтан бәла киләме, сөенечме – алар барысы да бәндәнең рухи үсешенә бер этәргеч була. Бәла-казалар, газап-интегүләрне андый затлар бер рәхмәт буларак кабул итә. Нәкъ Хәзрәти Ибраһим галәйһис-сәләәм кебек, хәтта Җәбраилне дә бер чара буларак кулланудан баш тарталар, чөнки алар Хак Тәгаләне тануда иң югары дәрәҗәгә ирешкәннәр. Яктылыкка эләгү өчен үзен һәлак иткән күбәләкләрдән аларның һич аермасы калмый, дип әйтә алабыз.

Ләкин шуңа игътибар итү кирәк: утның Хәзрәти Ибраһимне яндырмавын бер үрнәк итеп алып, берәр кешенең үзенә карата да шундый ук нәтиҗә күзәтелүен көтүе бәндәлек чикләрен белмәү дигән сүз. Бу исә кайгы-хәсрәткә китерә. Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ әлеге хакыйкатьне бик матур телгә ала: «Аллаһ юлында утка керү дигән нәрсә бар. Ләкин утка сикергәнче, үзеңдә Ибраһим белән тиң сыйфатларның булу-булмавын тикшер! Чөнки ут сине түгел, Ибраһимнәрне таный һәм аларны яндырмый!..».

Кыскасы, бер бәндәнең камил затлар һәм чыннан да югары дәрәҗәгә ия кешеләр белән үзен чагыштыруы куркыныч нәтиҗәләргә илтә торган урынсыз наданлык санала. Бу очракта без мөмкинлегебез чикләрендә чарасын күрергә һәм, калганын Аллаһка тапшырып, Аңа сыеныраг тиешбез. Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Үзенең Аллаһ каршындагы урынын белергә теләүче Аллаһ Тәгаләнең үз каршындагы урынына карасын! Чөнки Аллаһ Тәгалә колын ул Аңа биргән урынга куя!»* – дип нәсыйхәт бирә (Хаким, «Мүстәдрәк», I, 672/1820).

Түбәндәге вакыйга бу хакыйкатьне бик үтемле раслый:

Риваятькә күрә, Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Харисә радыйаллаһу ганһедән: *«Әй, Харисә, таңны ничек каршыладың?»* – дип сорый. Харисә радыйаллаһу ганһе: «Чын мөэмин булып!» – дип җавап бирә.

Шуннан Пәйгамбәр Әфәндебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Әй, Харисә! Һәр хакыйкатьнең һәм күренешнең бер дәлиле бар. Синең иманыңның дәлиле нинди соң?»* – дигән сорау куя. Харисә радыйаллаһу ганһе: «Йә, Рәсүлүллаһ! Дөньялыктан йөз чөергәч, көннәремне сусыз, төннәрем йокысыз уза. Раббымның гарешен ап-ачык күрермен кебекмен. Бер-берсен зиярәт кылган җәннәт әһелләре белән бер-берсенең дошманына әверелгән җәһәннәм әһелләрен күрер кебекмен», – дип әйтә.

Моңа каршы Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Җитәр, йә, Харисә! Бу халәтеңне сакла! Син – йөрәгең Аллаһ нурландырган бер зат»*, – дип белдерә (Хәйсәми, «Мәҗмагуз-Зәваид», I, 57).

Шулай ук Харисә радыйаллаһу ганһе турында Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Кем дә кем йөрәген Аллаһ нурландырган берәр шәхесне күрергә теләсә, Харисәгә карасын»*, – дигән (Ибне Һаҗәр, «Әл-Исабә», I, 289).

Монда сүз аяти кәримәдә:

رَّضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ وَرَضُوا عَنْهُ

**«...Аллаһ алардан разый, алар да Аннан разыйлар...»** – дип телгә алынган изге затларның хәле турында бара («әл-Бәййинә», 8). Мондый изге бәндәләр Сөләйман галәйһис-сәләәм шикелле:

رَبِّ أَوْزِعْنِي أَنْ أَشْكُرَ نِعْمَتَكَ الَّتِي أَنْعَمْتَ عَلَيَّ وَعَلَىٰ وَالِدَيَّ
وَأَنْ أَعْمَلَ صَالِحًا تَرْضَاهُ وَأَدْخِلْنِي بِرَحْمَتِكَ فِي عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ

**«...И, Раббым! Миңа һәм ата-анама биргән нигъмәтеңә шөкер итүемне, Син разый булган (изге) бер гамәл эшләвемне миңа илһам ит һәм рәхмәтең белән мине изге колларың арасына керт»**, – дип дога кылалар («ән-Нәмел», 19).

Җәнабел-Хак башка бер аяти кәримәдә болай ди:

وَمِنَ النَّاسِ مَنْ يَشْرِي نَفْسَهُ ابْتِغَاءَ مَرْضَاتِ اللَّهِ وَاللَّهُ رَءُوفٌ بِالْعِبَادِ

**«Кешеләр арасында шундые бар ки: Аллаһның ризалыгын алыр өчен ул җанын сата (Аллаһның ризалыгы бәрабәренә, кирәк икән, бөтен шәхси мәнфәгатьләреннән баш тарта). Аллаһ – колларга карата бик Мәрхәмәтле»** («әл-Бәкара», 207).

Аяти кәримәнең иңдерелү сәбәбе игътибарга лаек.

Суһәйб Руми радыйаллаһу ганһе Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына һиҗрәт кылу нияте белән Мәккәдән чыгып киткәч, корәешлеләрдән бер төркем, аны тотып алып, кире Мәккәгә кайтару өчен, артыннан куа чыга. Үзенең эзенә төшкәннәрен аңлагач, Суһәйб радыйаллаһу ганһе дөясеннән төшеп аягына баса да, садагыннан бер ук чыгарып, аны җәясенә куя һәм көтә башлый. Корәешлеләр бер ук ату ераклыгы кадәр якынайгач, аларга кычкыра: «Әй, корәеш кешеләре! Сездән иң оста укчы икәнемне беләсез. Сез миңа килеп җиткәнче садагымдагы бөтен укларны өстегезгә яудырачакмын, аннары кылычымны чыгарып, кулымда шуның соңгы кисәге калганчы сезнең белән сугышачакмын, менә шуннан соң гына минем белән ни телисез, шуны эшли аласыз. Әмма моның урынына, теләсәгез, Мәккәдә малларымны кайда яшереп калдырганымны әйтә алам, барып алыгыз һәм шулар хакына миңа юл

бирегез, кагылмагыз». Корәешлеләр тәкъдимне кабул итә (Ибне Җәүзи, «Задүл-Мәсир», I, 223; Ибне Кәсир, «Тәфсир», I, 260–261).

Шуннан соң Суһәйб радыйаллаһу ганһе, вакытны сузмыйча, Мәдинәгә таба юлга кузгала. Аллаһ Тәгалә исә Мәдинәдә Рәсүленә югарыда искә алынган аятьне иңдерә. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез, Суһәйбне күргәч, аңа: *«Сәүдәң керемле булды, әй, Суһәйб!»* – дип хәбәр итә. Суһәйб радыйаллаһу ганһе: «Йә, Рәсүлүллаһ! Юлда мине узып, Сезгә бу хакта хәбәремне тапшырырлык һичкем булмагач, минем башымнан үткәннәрне Сезгә бары Җәбраил генә белдергән булырга тиеш», – дип әйтә (Хаким, «Мүстәдрәк», III том, 450–452 б.).

Аяти кәримәләрдә болай диелә:

وَعَدَ اللّٰهُ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا
وَمَسَاكِنَ طَيِّبَةً فِي جَنَّاتِ عَدْنٍ وَرِضْوَانٌ مِنَ اللّٰهِ أَكْبَرُ ذٰلِكَ هُوَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ

**«Иманлы ирләр белән иманлы хатыннарның берәүләре – икенчеләренең вәлиләре. Алар игелеккә әмер итәләр, тыелганнардан тыялар, намазлар укыйлар, зәкят бирәләр, Аллаһка һәм Аның Рәсүленә итагать итәләр. Әнә шуларга Аллаһ рәхмәт итәчәк. Һичшиксез, Аллаһ – Бөек, Хикмәт иясе»** («әт-Тәүбә», 71).

وَعَدَ اللّٰهُ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ خَالِدِينَ فِيهَا
وَمَسَاكِنَ طَيِّبَةً فِي جَنَّاتِ عَدْنٍ وَرِضْوَانٌ مِنَ اللّٰهِ أَكْبَرُ ذٰلِكَ هُوَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ

**«Аллаһ мөэмин ирләргә һәм мөэмин хатыннарга – асларыннан елгалар аккан һәм алар эчендә мәңге калачак җәннәтләр, шулай ук, Гаден җәннәтләрендә бик әйбәт тораклар вәгъдә итте. Аллаһның ризалыгы исә өстенрәк. Әнә шул – зур котылу инде»** («әт-Тәүбә», 72).

Искә алынган барлык нигъмәтләр иң алдынгы иман һәм хезмәт ияләренә вәгъдә ителә. Аллаһның ризалыгына китергән кечкенә генә берәр нәрсә дә югарыда саналган җәннәт нигъмәтләренең һәркайсыннан зуррак, әһәмиятлерәк, чөнки һәр хәерле нәрсәнең, һәр шатлыкның, һәр дәрәҗәнең һәм һәр хөрмәтле урынның таяныч ноктасы әнә шуннан гыйбарәт.

Аллаһ Тәгалә Үзенең ризалыгын алырга тырышып, Аның юлында малларын, көчләрен сарыф иткән изге колларын мактап телгә ала:

وَمَثَلُ الَّذِينَ يُنْفِقُونَ أَمْوَالَهُمُ ابْتِغَاءَ مَرْضَاتِ اللّٰهِ وَتَثْبِيتًا مِنْ أَنْفُسِهِمْ كَمَثَلِ جَنَّةٍ بِرَبْوَةٍ
أَصَابَهَا وَابِلٌ فَآتَتْ أُكُلَهَا ضِعْفَيْنِ فَإِنْ لَمْ يُصِبْهَا وَابِلٌ فَطَلٌّ وَاللّٰهُ بِمَا تَعْمَلُونَ بَصِيرٌ

**«Аллаһның ризалыгын өмет итеп һәм үзләренең күңелләрен (иман белән) ныгытыр өчен (әҗере булачагына шөбһәсез ышанып), малларын сарыф итүчеләрнең мисалы – биек җирдәге бер бакча кебек; аны эре тамчылы яңгыр сугарса, җимешен ике кат бирер. Ләкин аны эре тамчылы яңгыр сугармаса да, сибәләп үткән яңгыр (да җитәр)! Аллаһ – сезнең ни кылганнарыгызны Күрүче»** («әл-Бәкара», 265).

وَالَّذِينَ صَبَرُوا ابْتِغَاءَ وَجْهِ رَبِّهِمْ وَأَقَامُوا الصَّلَاةَ وَأَنْفَقُوا مِمَّا رَزَقْنَاهُمْ سِرًّا
وَعَلَانِيَةً وَيَدْرَءُونَ بِالْحَسَنَةِ السَّيِّئَةَ أُولَئِكَ لَهُمْ عُقْبَى الدَّارِ

**«Янә ул кешеләр (мөэминнәр) ки, алар Раббыларының Затына (ризалыгына) омтылып, сабыр итәләр, намазны укыйлар, Без ризыкландырган нәрсәләрдән яшерен һәм ачыктан-ачык (Аллаһ юлында) сарыф итәләр, начар нәрсәне игелек белән кайтаралар. Алар өчен – (дөнья йортыннан соң күркәм) Ахирәт йорты»** («әр-Рәгъд», 22).

Хак Тәгалә юлында кеше күтәрелә алачак иң югары дәрәҗә Аллаһ Тәгаләнең колыннан риза булуына ирешүдән гыйбарәт, бу исә бәндәнең Аллаһтан ризалыгы һәм үзен Аңа багышлавы өчен бер әҗер булып тора.

Гомәр ибне Габделгазиз үзеннән: «Нәрсә яратасың?» – дип сораучыларга: «Минем шатлыкларым бары тәкъдиремдә генә. Мин Аллаһ Тәгалә хөкемен яратам...» – дип әйткән.

Аяти кәримәдә болай диелә:

قَالَ اللَّهُ هَذَا يَوْمُ يَنْفَعُ الصَّادِقِينَ صِدْقُهُمْ لَهُمْ جَنَّاتٌ تَجْرِي مِنْ تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ
خَالِدِينَ فِيهَا أَبَدًا رَضِيَ اللَّهُ عَنْهُمْ وَرَضُوا عَنْهُ ذَلِكَ الْفَوْزُ الْعَظِيمُ

**«(Кыямәт көнне) Аллаһы Тәгалә әйтте: “Бу – тугрыларга тугрылыклары файда китерәчәк көн. Аларга асларыннан елгалар аккан җәннәтләр булыр. Алар анда мәңге калачак. Аллаһ алардан разый, алар да Аннан разыйлар. Бу – бик зур уңыш”»** («әл-Маидә», 119).

Риваятькә күрә, Аллаһ Тәгалә җәннәт әһелләренә: «Риза булдыгызмы? Канәгатьмесез?» – дип дәшәчәк, тегеләр исә: «И, Раббыбыз, ничек канәгать булмыйк инде! Безгә башка колларыңнан һичкайсына бирмәгән нигъмәтләрне бирдең ләбаса», – дип әйтәчәк. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә: «Сезгә моннан да зуррагын бирәчәкмен», – дип белдерәчәк. «Моннан да яхшырак тагын ни була ала, йә, Раббы?» – диярләр. Әнә шулчакта Аллаһ Тәгалә: «Сездән риза булачакмын һәм инде сезгә мәңге газап җибәрмәячәкмен», – дип хәбәр итәчәк (Бохари, «Рикак», 51; Мөслим, «Җәннәт», 9).

Ризалык – мәхәббәтнең иң ахыргы җимеше. Күңеле сөю белән тулы кол Раббысыннан килгән һәрнәрсәне мәхәббәтенә нисбәтле канәгатьлек белән кабул итәр. Сөю белән сугарылган бәндә бәла-казаның газабын тойганда да, моңа шулкадәр риза була ки, андый авыртулар, иза-җәфалар күңеленә хуш килә башлар, шуларга омтылыр. Монда сүз киләчәктә алачак әҗер-савап бәрабәренә хәзерге вакытлы авыртуларга, бәлаләргә риза булу турында бара. Шакик әл-Бәлхи рәхмәтуллаһи галәйһи: «Авырлыкның әҗерен белүче аннан котылырга омтылмас!» – дигән. Чөнки шифа алу өчен, авыру кешеләр даруларның тәмсезлегенә игътибар итеп тормый, хәтта бик авыр һәм куркыныч операцияләргә дә үз теләкләре белән керәләр.

Шулай да ризалыкның тагын да югарырак дәрәҗәсе сөйгәненңнең күңеленә хуш килү максатына бәйле. Раббының ризалыгы исә җәннәт нигъмәтләреннән өстенрәк. Бу дәрәҗәгә ирешкән колның мәхәббәте аны авыртуларны тоймаслык халәттә яшәтә. Сөю тәмен татымаганнар бу халәтне аңламый, ә гашыйкларның монда бәян кылганнардан да гаҗәбрәк сыйфатлары бар әле.

Шушы барлык сыйфатларга, югары дәрәҗәләргә карамастан, түбәндәге мәсьәләне дә ассызыклау кирәк:

Бәла-казалар һәм газапларның әҗере зур дип кенә, Хак Тәгаләдән төрле авырлыклар, казалар белән сынавын сорарга ярамый, чөнки кол үзе чыдый алырлык йөкнең авырлыгын дөрес чамаламаска һәм үзе күтәрә алмаган бәлаләр астында изелеп-басылып калырга мөмкин. Ә инде бәла-казалар Хак Тәгаләдән килә икән, шуны белергә кирәк, Аллаһ бер бәндәгә дә ул күтәрә алмаслык йөк салмый!

Бер заманнарда Җан Баба дип йөртелгән бер кеше яшәгән. Аллаһны сөюдән шулкадәр ләззәтләнеп, дөньялык эш-гамәлләреннән ваз кичә һәм беркөнне, кулларын күтәреп, дога кыла: «Йә, Раббы! Синнән башка шатлык-бәхетем юк! Мине Үзең теләгәнчә сына!» Шуннан соң аңа бик авыр сынау җибәрелә. Яше өлкәнәеп, авырлыкларга бирешеп, түземлеге бетә башлагач, күңеленә догасы өчен үкенеч хисе үтеп керә. Ул, кече яшьтәге шәкертләр белем алган мәктәп ишек төбенә килеп, каршына чыккан һәр сабыйга: «Балакаем! Бу алдакчы карт абзагыз өчен дога кылыгызчы, Аллаһ аңа шифа насыйп итсен!» – дип ялварыр хәлгә төшә.

Шулай ук гөнаһ гамәлләргә һәм кешене бозыклыкка илтә торган нәрсәләргә түземлек күрсәтү дә ризалык саналмый. Аллаһка каршы гыйсьян, бозыклыкка һәм көферлеккә риза булып яшәү – иң зур наданлык һәм ваемсызлык. Бу мәсьәләдә илаһи кисәтүләр бихисап. Аларның берсендә болай диелә:

لَا يَتَّخِذِ الْمُؤْمِنُونَ الْكَافِرِينَ أَوْلِيَاءَ مِنْ دُونِ الْمُؤْمِنِينَ

**«Мөэминнәр мөэминнәрне калдырып, кяферләрне дус итмәсеннәр!»** («Әли Гыймран», 28).

Ягъни яман затларга һәм алар кылган әшәкелекләргә каршы дәшми тору ризалык була алмый.

Бөек шәхесләрнең шундый камиллеккә ничек ирешкәнлекләренә игътибар иткәндә, аларның һәрберсенең мең дә бер газап, төрле авырлыклар аша үтеп, авыру-газаплар утында көеп кенә шундый камиллек дәрәҗәсен яулаганын күрә алабыз.

Игътибарга лаек үрнәк: күңел дөньясын рухи камиллек нурлары белән яктырткан атаклы әүлия Баһаутдин Накшбәнди куддисә сирруһ хәзрәтләренә мөршиде Әмир Күлал куддисә сирруһ тарафыннан җиде ел кешеләргә хезмәт итү, һичкем якын килмәгән авыру хайваннарны дәвалау һәм кешеләр үтеп йөри торган юлларны чистарту кебек вазифалар йөкләнә. Баһаутдин Накшбәнди боларның барысын да бик бирелеп үти. Ниһаять, бу хезмәтләрендә күргән газаплар, изаланулар һәм авырлыклар аның һич ирешә алмаслык дәрәҗәдәге илаһи серләрне тануына юл ача. Аның шундый бөек дәрәҗәгә ирешкәндәге кече күңеллелеген, һәрнәрсәдән тыелуын түбәндәге шигырь юллары бик күркәм тасвирлый:

«Галәм – бодай, мин – салам,

Һәркем яхшы, мин яман!»

Мондый хакыйкатькә бәйле рәвештә Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ: «Гөнаһлар коллыгыннан котылуның бердәнбер чарасы – сынаулар, газаплар һәм иза-җәфалар!» – дип әйткән.

Ләкин алар да гафләттән уянуга китермәсә, дөньялыкка күңел бирүчеләр, ягъни нәфес теләкләренә ияреп яшәүне бәхет дип санаучылар, нәфесләренең азгын тырнакларында һәлак була. Әүлиялар фикеренчә, чын бәла, чын хәсрәт менә шунда инде.

Ахирәт бәхете өчен дөньяның вакытлы ләззәтләренә, алдаучы көйаһәңнәренә күңел бирмәү таләп ителә. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең хөрмәтле хатыннарыннан Хафса анабыз Аллаһ Рәсүленең дөньяга карата мөнәсәбәтен чагылдырган бер вакыйганы искә ала:

«Без, бер келәмне икегә бөкләп, Аңа ятак әзерли идек. Берьюлы аны дүрт кат итеп бөкләгән идек һәм Ул төнге намазга тора алмады. Шуннан соң Ул астына ни җәелгәнен сорады һәм һәрвакыттача итеп җәяргә кушты. Аны артык кайгыртулары аркасында канәгатьсезлеген күрсәтте» (Тирмизи, «Шәмаил», 154 б.).

Илаһи якынлык, илаһи дуслык юлы мәхәббәткә, сөйгәннәргә охшарга тырышуга нигезләнә. Гашыйклар сөйгәннәреннән килгән нәрсәне күңелләренә

якын итәргә, ошатырга тиеш. Гашыйклар сөйгәннәрен телләреннән, күңелләреннән һич төшермәс. Иманлы тормышның тәмен, ләззәтен тоярга теләгән йөрәкләр дә Аллаһны зикер итүдән туктамас. Баскан килеш тә, утырганда да, ятканда да – һәркайчан Аны зикер итеп, күкләр һәм җирнең яратылуына бәйле олуг хикмәтләрне күзәтә-күзәтә, болай диярләр:

رَبَّنَا مَا خَلَقْتَ هَذَا بَاطِلًا سُبْحَانَكَ فَقِنَا عَذَابَ النَّارِ

**«…И, Раббыбыз! Син моны юкка яралтмадың. Син пакьсең! Безне Ут газабыннан сакла!»** («Әли Гыймран», 191).

Аллаһ Тәгалә Үзеннән ихлас риза булган һәр колына әйтер:

ارْجِعِي إِلَىٰ رَبِّكِ رَاضِيَةً مَرْضِيَّةً فَادْخُلِي فِي عِبَادِي وَادْخُلِي جَنَّتِي

**«Разый булган һәм разыйлык алган буларак Раббыңа кайт! Кер (изге, сайлап алынган) колларым арасына! Кер җәннәтемә!»** («әл-Фәҗр», 28–30).

Җәнабел-Хак андый колларын мәңгелек нигъмәтләре белән бүләкләп, Үзенең гүзәл йөзен күрү мөмкинлеге белән хөрмәтләр.

Йә, Рабб ы! Безне Үз ризалыгыңа лаек, Үзеңә тәвәккәл кылган һәм буйсынган чын колларың булырга насыйп ит!

Амин!..

*Хәзрәти Әйюб галәйһис-сәләәм*





ХӘЗРӘТИ

# ЮНЫС

*галәйһиссәләм*

***Тирән ихласлык белән тәүбә, дога һәм зикер аша илаһи хакыйкатькә чумып, караңгылыкларны кичкән***

# ХӘЗРӘТИ ЮНЫС

***галәйһис-сәләәм***

Коръәни-Кәримдә аның исемендәге бер сүрә иңдерелгән Хәзрәти Юныс галәйһис-сәләәм Ассирия дәүләте башкаласы Ниневия[162] халкына пәйгамбәр итеп җибәрелә. Б.э. кадәр сигезенче гасырларда яшәгәнлеге фаразлана. Атасы Мәтта исемле изге кеше була.

Юныс галәйһис-сәләәм Ниневиядә туып үсә, утыз яшенә җиткәч, Хак Тәгалә аңа пәйгамбәрлек вазифасын йөкли. Хәзрәти Гали радыйаллаһу ганһе: «Юныс галәйһис-сәләәм утыз яшендә пәйгамбәр була һәм күп еллар кавемен иманга өнди», – дип әйтә.

Хәзрәти Юнысның пәйгамбәрлеге турында Коръәни-Кәримдә болай дип хәбәр ителә:

وَإِنَّ يُونُسَ لَمِنَ الْمُرْسَلِينَ

**«Юныс та – (пәйгамбәр итеп) җибәрелгәннәрдән»** («әс-Саффат», 139).

وَأَرْسَلْنَاهُ إِلَىٰ مِائَةِ أَلْفٍ أَوْ يَزِيدُونَ

**«Без аны йөз меңгә (кешегә) җибәрдек яки алар күбрәкләр иде»** («әс-Саффат», 147).

إِنَّا أَوْحَيْنَا إِلَيْكَ كَمَا أَوْحَيْنَا إِلَىٰ نُوحٍ وَالنَّبِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ وَأَوْحَيْنَا إِلَىٰ إِبْرَاهِيمَ وَإِسْمَاعِيلَ وَإِسْحَاقَ وَيَعْقُوبَ وَالْأَسْبَاطِ وَعِيسَىٰ وَأَيُّوبَ وَيُونُسَ وَهَارُونَ وَسُلَيْمَانَ وَآتَيْنَا دَاوُودَ زَبُورًا

**«(Хәбибем!) Һичшиксез, Без, Нухка һәм аңардан соңгы пәйгамбәрләргә вәхи җибәргән кебек, сиңа да вәхи иттек. Без Ибраһимгә, Исмәгыйльгә, Исхакка, Ягъкубка, аларның оныкларына, Гайсәгә, Әйюбкә, Юныска, Һарунга һәм Сөләйманга вәхи иттек. Давытка исә Зәбурны бирдек»** («ән-Ниса», 163).

### Ниневиялеләр

Ниневия халкы потларга һәм һәйкәлләргә табына, бик явыз була. Юныс галәйһис-сәләәм тәүхид дингә өнди башлагач, аңа нибары ике кеше генә иман

162. Ниневия шәһәре Тигр елгасы буенда, хәзерге Мосул каласы тирәсендә урнашкан булган.

китерә. Аларның берсе галим, акыллы кеше, икенчесе күп гыйбадәт кылучы диндар була. Башкалар исә Хәзрәти Юныска: «Арабызда шулкадәр каһиннәр, галимнәр һәм сәнгатькярләребез булган хәлдә, син берүзең чыгып, ата-бабаларыбыз юлының ялгыш икәнлеген сөйлисең! Тәңребезләреңне кире кагасың! Син һичкем күнекмәгән гадәтләргә безне бәйләп куярга телисеңме?!» – диләр. Ләкин мондый сүзләр белән генә тыелып калмыйча, Юныс галәйһис-сәләәмне төрлечә җәфалый башлыйлар. Хәзрәти Юныс исә алар кылганнарга сабырлык белән түзә, аларны мәрхәмәтлелек белән тәүхид дингә өндәвен барыбер дәвам итә, Аллаһның газабы авыр икәнен исләренә төшереп тора, ләкин ниневиялеләр бу кисәтүләргә көлеп кенә карый: «Бер кешенең хәтерен калдырган өчен газап килеп, һәркемне юкка чыгарачак икән, кая, килсен әле ул газап!»

Юныс галәйһис-сәләәм кавеменең көферлеккә шулай киреләнеп ябышуына бик кайгыра. Башка түзеп тора алмыйча, илаһи рөхсәтне көтеп тормастан, бу халыкны ташлап китеп бара. Юлда чакта Җәнабел-Хак аңа: «И, Юныс! Кире кайт та тагын кырык көн аларны иманга чакыр!» – дип вәхи иңдерә. Мондый әмер алгач, Юныс галәйһис-сәләәм кабат кавеме янына кайтып, халкына Аллаһның кушканнары һәм газабы турында хәбәр тапшыра. Тик ниневиялеләр барыбер колак салмый. Вәгъдә ителгән көннәрдән утыз җиде көне узганда, кавеме әле иманга килмәгән була. Хәзрәти Юныс: «Алайса өч көннән соң башыгызга төшәчәк газапны көтегез! Моның бер билгесе буларак, әүвәл йөзләрегезнең саргайганын күрәчәксез!» – дип, янә Аллаһның әмерен көтеп тора алмыйча, кайгы-хәсрәткә чумып, халкын калдырып китә. Кавеменнән аерылу – илаһи вазифаны үтәүдән качу да, бу вазифаны йөкләүчегә каршы баш күтәрү дә түгел. Изге дәгъватка колак салмаган, кушканны үтәмәгән бозык кавемнән ераккарак китү генә була.

### Иман, тәүбә һәм гафу итү

Шул чакта Юныс галәйһис-сәләәм хәбәр иткән көн килеп тә җитә. Илаһи газап галәмәте буларак, бөтен ниневиялеләрнең йөзләре саргая һәм сула. Әнә шул мизгелдә алар һәрнәрсәне аңлап ала. Бер-берсенә: «Бу бит Юныс әйткән газап билгесе! Аның ялган сөйләгәнен моңарчы беркайчан да күргәнебез юк иде», – диешеп, башларына килгән газаптан бик нык куркуга төшәләр.

Күк йөзе карала башлый, һәркем кычкырыша-елаша, бичара хәлдә берәр котылыр тишек эзли. Кешеләр үзара: «Әгәр Юныс арабызда булса, курыкмагыз! Әгәр киткән булса, бу газап безне һәлак итәчәк!» – дип сөйләшәләр. Алар бик үкенә. Кылган эшләре аркасында, йөрәкләрендәге үкенеч хисе тулып ташый, чөнки илаһи газап тәмам якынайган була. Нишләргә белмичә, тәүбә итү теләге белән янып, бер изге зат янына йөгереп килеп җитәләр. Ул исә: «Әле газап килергә ике көн бар. Хәзер шушы биек тауга (тәүбә тавына) менегез! Бер-берегезне кичереп, кемнең нинди хакына кергән булсагыз, аны иясенә кайтарыгыз! Шуннан соң Юнысның Раббысына багышлап корбаннар

чалыгыз һәм шуны олысы-кечесе, ярлы-бай – һәркем ашасын! Аннары башыгызны күтәреп: “И, Юнысның Раббысы! Без тәүбәгә килдек. Сиңа инандык. Юнысның пәйгамбәрлеген дә кабул иттек. Юнысны тапкач та, аннан Синең кушканнарыңны һәм тыйганнарыңны белешеп, үтәячәкбез!” – дип ялварыгыз!..» – дип киңәш бирә.

Күз яшьләренә буыла-буыла, ниневиялеләр изге бәндә кушканнарны башкара. Аллаһ Тәгалә «Рахман» исем-шәрифе белән аларның тәүбәләрен кабул итә һәм өсләреннән илаһи газапны алып ташлый. Бу – җомга, гашура көне була. Әлеге вакыйга Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә искә алына:

فَلَوْلَا كَانَتْ قَرْيَةٌ آمَنَتْ فَنَفَعَهَا إِيمَانُهَا إِلَّا قَوْمَ يُونُسَ لَمَّا آمَنُوا كَشَفْنَا
عَنْهُمْ عَذَابَ الْخِزْيِ فِي الْحَيَاةِ الدُّنْيَا وَمَتَّعْنَاهُمْ إِلَىٰ حِينٍ

**«Юнысның кавеменнән тыш, иман итеп тә, иманнары аңа файда биргән бер сала (әһеле) булдымы соң? Алар иман китергәч, Без алардан дөнья тормышында хурлык газабын алдык һәм аларны бервакытка кадәр (әҗәлләре килгәнче яшәтеп) файдаландырдык!»** («Йунус», 98).

Имансызлыклары сәбәпле һәлакәткә дучар ителгәч, тәүбә итеп котылуга ирешкән бердәнбер кавем – Юныс галәйһис-сәләәм кавеме була. Бу – илаһи рәхмәтнең үзенчәлекле бер күренеше. «Йунус» сүрәсенең күп кенә аяти кәримәләре Рахманның рәхмәте илаһи газаптан көчлерәк, зуррак икәнлеген телгә ала.

**Хәзрәти Юныс Ниневиядән киткәч...**

Аяти кәримәдә болай диелә:

وَذَا النُّونِ إِذْ ذَهَبَ مُغَاضِبًا

**«Балык иясен дә (искә ал)! Менә ул ярсыган хәлдә киткән иде...»** («әл-Әнбия», 87).

Аятьтәге «балык иясе» дигән мәгънәне белдергән «Зүннун» Хәзрәти Юнысның кушаматы була. Әлеге кушаматны аны балык йотканга күрә тагалар.

Юныс галәйһис-сәләәм шәһәрдән чыгып киткәч, Тигр елгасы ярына килеп, бер көймәгә утыра. Коръәни-Кәримдә:

إِذْ أَبَقَ إِلَى الْفُلْكِ الْمَشْحُونِ

**«Ул төялгән көймәгә утырып качты»**, – дип хәбәр ителә («әс-Саффат», 140).

Күпмедер йөзеп баргач, көймә су уртасында туктый. Аны һич кузгата алмыйлар. Батабыз, дип борчыла башлыйлар. Халык бу бәхетсезлекнең сәбәбе

көймәдә берәр гөнаһлы бәндә утырганлыктан, дип уйлый. Моның кем икәнлеген ачыклау өчен, җирәбә сикертәләр. Шобага Хәзрәти Юныска чыга. Ул, үз башына төшкән бу эшнең бер сынау икәнен уйлап, Аллаһка тәвәккәл кыла да: «Әйе, ул гөнаһлы кол мин булам!» – дип белдерә. Ләкин көймәдәгеләр аның үз-үзен тотышыннан изге бәндә икәнен аңлап, тагын берничә тапкыр шобага тарталар. Тик барысында да җирәбә Юныс галәйһис-сәләәмгә чыга. Ахыр чиктә халык, чарасыз калып: «Һәрхәлдә, бу колның берәр гаебе булырга тиеш!» – дип, Хәзрәти Юнысны суга ыргыталар. Аяти кәримәләрдә бу хакта болай диелә:

فَسَاهَمَ فَكَانَ مِنَ الْمُدْحَضِينَ

**«(Көймәдәгеләр белән) шобага тартты һәм (Юныс) оттырганнардан булды»** («әс-Саффат», 141).

فَظَنَّ أَنْ لَنْ نَقْدِرَ عَلَيْهِ

**«...(Ул) Без аңа каршы хөкем бирмәячәкбез дип санаган иде...»** («әл-Әнбия», 87).

فَالْتَقَمَهُ الْحُوتُ وَهُوَ مُلِيمٌ

**«Аны (Юнысны) балык йотты. Ул (үзен) әрләгән бер кеше иде»** («әс-Саффат», 142).

Инде Хәзрәти Юныс бер балык карынына эләгә. Бу бер караңгы урын була. Хәзрәти Юныс әле тере, үз акылында кала. Җәнабел-Хак балыкка Юнысны яраламаска, аның сөякләренә зыян китермәскә куша. Юныс галәйһис-сәләәм, илаһи тәкъдиргә риза булып, үз язмышын Раббысы карамагына тапшыра. Аяти кәримәдә бу хәл түбәндәгечә искә алына:

فَنَادَىٰ فِي الظُّلُمَاتِ أَنْ لَا إِلَٰهَ إِلَّا أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ

**«...(Һәм) караңгылыклар эчендә (Юныс бик кайгылы хәлдә Раббысына): “Синнән башка һичбер илаһ юк! Син пакь! Һичшиксез, мин залимнәрдән булдым!” – дип дәште»** («әл-Әнбия», 87).

Ул арада Хәзрәти Юныс балык карынында ниндидер тавышлар ишетеп, аларның ни-нәрсә булуы белән кызыксына. Аллаһ Тәгалә вәхи аша аның балык карынында икәнен хәбәр итә һәм: «И, Юныс! Бу авазлар – диңгездә зикер әйтүче җан ияләренең тавышы ул», – дип аңлата.

Хәтта шундый авыр, кысан шартларда да Хәзрәти Юныс һәрвакыттагыча Җәнабел-Хакны тәсбих һәм зикер итүдән туктамаска тырыша. Һәрдаим тәүбә-истигъфар һәм догадан өзелми. Фәрештәләр Хәзрәти Юнысның хәл-

әхвәле хакында белеп алгач, Аллаһтан аңа шәфәгать сорыйлар. Ниһаять Җәнабел-Хак Хәзрәти Юныcның:

لَا إِلَهَ إِلَّا أَنْتَ سُبْحَانَكَ إِنِّي كُنْتُ مِنَ الظَّالِمِينَ

**«Синнән башка һичбер илаһ юк! Син пакь! Һичшиксез, мин залимнәрдән булдым!»** – дип күп-күп тәсбихенә җавап итеп, әлеге мөбарәк пәйгамбәренең хатасын кичерә:

فَاسْتَجَبْنَا لَهُ وَنَجَّيْنَاهُ مِنَ الْغَمِّ وَكَذَلِكَ نُنْجِي الْمُؤْمِنِينَ

**«Без аңа җавап бирдек һәм аны хәсрәтеннән коткардык. Мөэминнәрне дә шулай коткарырбыз»** («әл-Әнбия», 88).

Бу гафуның бердәнбер сәбәбе Юныс галәйһис-сәләәмнең бик күп тәсбих әйтү була:

فَلَوْلَا أَنَّهُ كَانَ مِنَ الْمُسَبِّحِينَ لَلَبِثَ فِي بَطْنِهِ إِلَىٰ يَوْمِ يُبْعَثُونَ

**«Әгәр дә ул тәсбих итүчеләрдән булмаса. Алар терелтеләчәк көнгә кадәр аның карынында көтәчәк иде»** («әс-Саффат», 143–144).

Юныс галәйһис-сәләәм Раббыны зикер кылу, хатасын аңлап, Аңа буйсынуы хакына бәладән котыла. Әнә шул сыйфатлары аңа карата рәхмәт һәм нигъмәт сәбәбенә әйләнә.

Шуны да искә алу мөһим: Юныс галәйһис-сәләәм кавемен һәлак иткәнче бирелгән кырык көнлек срокның 37 көнен сабыр итә, өч көненә түземлеге җитми. Моңа каршы Аллаһ Тәгалә дә аңа балык карынында сабырлык иттерү кебек бик зур сынау уздыра. Ахыр чиктә Хәзрәти Юнысны үзендә әманәт кебек йөрткән балык, Аллаһның кушу буенча, аны ярга чыгара. Җәнабел-Хак әйтә:

فَنَبَذْنَاهُ بِالْعَرَاءِ وَهُوَ سَقِيمٌ وَأَنْبَتْنَا عَلَيْهِ شَجَرَةً مِنْ يَقْطِينٍ

**«Ул авыру хәлдә булганда, Без аны (тышка чыгарып) буш бер җиргә ташладык. Һәм аның өстенә (күләгә ясасын өчен) кабак агачы үстердек»** («әс-Саффат», 145–146).

Балык аны карынында чыгарып, ярга ташлаганда, Юныс галәйһис-сәләәм бик хәлсезләнгән, йончыккан, авыру, ярдәмгә мохтаҗ була. Тәне – гүя сәлперәйгән хәлендә. Һава да шактый эссе. Аллаһ Тәгалә, аны кояшның яндыргыч нурларыннан саклау өчен, киң яфраклы бер үсемлек үстерә. Аның күләгәсендә чебен-черки кебек хәшәрәтләр дә булмый. Җәнабел-Хак бу үсемлектән Хәзрәти Юныска сөт тамдыра.

Хәл җыйгач, Хәзрәти Юныс Ниневиягә юнәлә. Шәһәргә якынайгач, бер көтүчене очратып, кавеменең хәлен сораша. Көтүче булып узганнарны сөйләп бирә. Кавеменең иман китереп, тәүбә иясе булуын, шул рәвешле Аллаһның аларны гафу итүен белдерә. Хәзер һәркем, илаһи әмерләрне җиткерсен өчен, Юныс галәйһис-сәләәмнең кайтуын көтә, дип әйтә.

Хәзрәти Юнысның кайтканлыгы турында хәбәр алгач, кавеме шундук аның янына җыела. Ул вакытта Юныс галәйһис-сәләәм намаз укыган була. Намаздан соң аны сагынудан кочаклап алып, гафу итүен үтенәләр. Аларга карата киң күңеллелек күрсәтеп, Хәзрәти Юныс Аллаһның кушканнары һәм тыйганнары турында сөйли. Шуннан соң кавеме Аллаһка һәм пәйгамбәренә итагать кылып, имин һәм тыныч тормышта яши. Аяти кәримәдә әйтелә:

فَآمَنُوا فَمَتَّعْنَاهُمْ إِلَىٰ حِينٍ

**«Алар иман иттеләр, (шуннан соң) Без исә аларны бервакытка кадәр яшәттек»** («әс-Саффат», 148).

Хак Тәгаләгә иман китерергә өндәп дәгъват кылучыларга сабырлык, тынычлык һәм ныклык белән эш йөртү тиеш. Кавеменең көферлегеннән тәмам туеп, моңа бик хәсрәтләнгәнгә күрә, Юныс галәйһис-сәләәм, илаһи вәхине көтеп тора алмыйча, халкын ташлап китә. Бер яктан караганда, бу сабырсызлык һәм ашыгучанлык дип бәяләнә ала. Авыр шартларга карамастан, мондый гамәл Хәзрәти Юныс өчен бер хата була.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм исә Мәккә мөшрикләренең золымына, кимсетүләренә, җәзаларына түзә, һиҗрәт турында илаһи әмер килгәнче, сабырлык белән көтә. Аллаһ Тәгалә «Исра» сүрәсенең бер үк вакытта дога да булып торган 80 нче аятендә Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә болай дип рөхсәт бирә:

إِلَّا رَحْمَةً مِنْ رَبِّكَ إِنَّ فَضْلَهُ كَانَ عَلَيْكَ كَبِيرًا

**«Әйт: “И, Раббым! Мине (керәчәк җиремә) тугры бер кертү белән керт һәм мине тугры бер чыгару белән чыгар. Үзеңнән миңа ярдәмгә көч бир!”»**

Юныс галәйһис-сәләәмнең кавемен рөхсәтсез калдырып китүе сәбәпле дә, Җәнабел-Хак Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә рәсүллек вазифасында авырлыкларга сабыр итү тиешлеге турында анык белдерә:

فَاصْبِرْ لِحُكْمِ رَبِّكَ وَلَا تَكُنْ كَصَاحِبِ الْحُوتِ إِذْ نَادَى وَهُوَ مَكْظُومٌ لَوْلَا أَنْ
تَدَارَكَهُ نِعْمَةٌ مِّنْ رَّبِّهِ لَنُبِذَ بِالْعَرَاءِ وَهُوَ مَذْمُومٌ فَاجْتَبَاهُ رَبُّهُ فَجَعَلَهُ مِنَ الصَّالِحِينَ

**«Раббыңның хөкеменә сабыр ит һәм балыкның юлдашы (Юныс) кебек булма. Менә ул борчулы бер хәлдә мөрәҗәгать итте. Әгәр дә аңа Раббыңнан бер нигъмәт ирешмәгән булса, ул хур ителгән буларак, буш бер җиргә чыгарып атылган булыр иде. Раббысы аны сайлады (вәхи җибәрде) һәм аны изге кешеләрдән итте»** («әл-Каләм», 48–50).

Юныс галәйһис-сәләам Аллаһны күп зикер итүчеләрдән булганга күрә, балык карынында кыяматкә кадәр калудан котылып, аннан чыгарылу бәхетенә ирешә. Шуңа күрә аяти кәримәдә: **«Ул авыру хәлдә булганда, Без аны (тышка чыгарып) буш бер җиргә ташладык!»** – дип белдерелә.

«Каләм» сүрәсенең 49 нчы аяте Юныс галәйһис-сәләам балык карыныннан чыгарылуга лаек табылганнан соңгы хәл белән бәйле. Әлеге аяти кәримәдән аңлашылганча, әгәр Аллаһ Тәгалә, Хәзрәти Юныcның тәүбәсен кабул итеп, аңа вәхи иңдереп, янә кавемен иманга өндәргә кайтаруны максат итеп куймаган булса, әлбәттә, ул һич ятышсыз караңгы урында калдырылыр иде. Ләкин тәүбәсе кабул ителеп, илаһи ярлыкауга лаек булгач, Хәзрәти Юныс бәладән котыла. Балык карыныннан бернинди үсемлексез, йорт-бинасыз, кешесез бер җиргә чыгарып ташланганда, ул җәзаланган һәм авыр хәлдә булмый. «Саффат» сүрәсендә әйтелгәнчә, матди, тышкы яктан хәлсезлеккә дучар ителсә дә, илаһи рәхмәт ярдәмендә бик тиз арада савыга. Саулыгы, көч-дәрте кайтарыла, чөнки ул Раббысының ярлыкавына һәм мәрхәмәтенә ирешкән изге күңелле пәйгамбәр була.

**Юныс галәйһис-сәләам кыйссасыннан алынырга тиешле сабаклар:**

1. Тәблигъ эшендә сабырлык, ныклык һәм игътибарлылыкның зарурлыгы.

2. Зикер белән тәүбә-истигъфарның әһәмияте.

3. Ихласлык белән кылынган тәүбәнең кабул ителүе.

4. Үлем куркынычы хәлендә кылынган тәүбәнең Юныс галәйһис-сәләамнең кавеменнән генә кабул ителүе. Ләкин монда туры мәгънәсендә үлем янаган мәлдәге халәт күздә тотылмый, чөнки Юныс галәйһис-сәләам кавеме тәүбә иткән вакытта, әле илаһи газап килмәгән була, бары аның билгеләре генә күренә. Хәзрәти Юныcның һичвакыт ялган сөйләмәгәнен хәтерләп, ниневиялеләр вәгъдә ителгән газапның һичшиксез киләчәген аңлый һәм шундук тәүбәгә килә. Ә башка һәлак ителгән кавемнәрдә хәл башкачарак була. Мәсәлән, Фиргавен газап чынга ашкач кына иманга килүен белдерә, өметсезлектән әйтелгән сүзләр генә булганга күрә, алар кабул ителми.

Юныс галәйһис-сәләамнең фазыйләте турында Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез тыйнаклык һәм түбәнчелек белән болай дип белдерә: *«”Юныс ибне Мәттадан хәерлерәкмен”, дип әйтү һичбер колга килешмәс!»* (Бохари, «Әнбия», 35; Мөслим, «Фәдаил», 166).

***Хәзрәти Юныс галәйһис-сәләам***





ХӘЗРӘТИ

# Ильяс

*галәйһиссәләм*

### *«Ильяска сәлам булсын!»*
### *дигән мактаулы сүзләр белән искә алырлык дан калдырган*

## ХӘЗРӘТИ ИЛЬЯС

### *галәйһис-сәләәм*

Һарун галәйһис-сәләәм нәселеннән булган Ильяс галәйһис-сәләәм пәйгамбәр итеп Бәни Исраил кавеменә җибәрелә. Аллаһ Тәгалә болай дип ачыклый:

وَإِنَّ إِلْيَاسَ لَمِنَ الْمُرْسَلِينَ

**«Һичшиксез, Ильяс та (пәйгамбәр итеп) җибәрелгәннәрдән»** («әс-Саффат», 123).

Исраил угыллары Палестинаны яулап алгач, кабиләләрнең берсе Бәгълбәк шәһәренә урнаша. Алар белән бер залим хөкемдар идарә итә. Риваятькә күрә, шәһәр элегрәк Бәк дип атала. Ләкин бу король Бәгъл дип аталган бер пот ясаттыра һәм халыкны шул потка табынырга мәҗбүр итә. Бәгъл белән Бәк исеме кушылып, шәһәр Бәгълбәк[163] дип йөртелә башлый. Хәзрәти Ильяс, тәүхид диннән ерагаеп ширеккә баткан бәндәләрне Хак Тәгаләгә иманга чакыру өчен, әнә шул калага пәйгамбәр итеп җибәрелә.

Бу халык табынган пот чама белән ун метр биеклектә итеп, алтыннан ясалган була. Ильяс галәйһис-сәләәм кала кешеләренә: «Бәгъл дигән потка табынудан баш тартыгыз! Һәрнәрсәнең яралтучысы булган Аллаһка иман китереп, гыйбадәт кылыгыз!» – дип мөрәҗәгать итә.

Коръәни-Кәримдә аның сүзләре китерелә:

إِذْ قَالَ لِقَوْمِهِ أَلَا تَتَّقُونَ أَتَدْعُونَ بَعْلًا وَتَذَرُونَ
أَحْسَنَ الْخَالِقِينَ اللَّهَ رَبَّكُمْ وَرَبَّ آبَائِكُمُ الْأَوَّلِينَ

**«Менә ул (Ильяс) кавеменә әйтте: “(Аллаһка каршы килүдән) һич курыкмыйсызмы? Бәгългә табынасыз, әмма шәкел бирүчеләрнең иң күркәмен калдырасызмы? Сезнең дә Раббыгыз, әүвәлге аталарыгызның да Раббысы булган Аллаһны (калдырасызмы)?»** («әс-Саффат», 124–126).

Ләкин Исраил угыллары Ильяс галәйһис-сәләәмнең үгет-нәсыйхәтләрен тыңламый. Аны каладан куып чыгаралар, шуңа күрә башларына төрле бәла-казалар һәм афәтләр ява. Ниһаять, хакыйкатьне төшенеп, Хәзрәти Ильяс-

163. Хәзер бу кала Багъләбәк дип атала.

ны табып алалар. Аңа иман китереп, бөтен авырлыклардан котылалар. Тик кавем азгынлыктан арына алмый, аның халкы диндә ныклык күрсәтмичә, баш күтәреп, туры юлдан тайпыла. Хәзрәти Ильясны аларны кабат-кабат үгетләсә дә, колак салмыйлар. Шуннан соң илаһи әмергә буйсынып, Ильяс галәйһис-сәләәм кавемне калдырып китә. Халык тәмам пыран-заран китерелә. Алар дөньялыкта да, ахирәттә дә җәзага һәм газапка дучар ителә. Аллаһ Тәгалә болай ди:

فَكَذَّبُوهُ فَإِنَّهُمْ لَمُحْضَرُونَ إِلَّا عِبَادَ اللَّهِ الْمُخْلَصِينَ

**«Алар аны (Ильясны) ялганда гаепләделәр, шул сәбәпле алар (җәһәннәмгә) җыелачаклар. Аллаһның ихласлы колларыннан тыш»** («әс-Саффат», 127–128).

Бәгълбәктән киткәч, Ильяс галәйһис-сәләәм бер авылга кагыла. Андагы кешеләрне иманга чакыра. Авыл халкы аның илаһи дәгъватын кабул итеп, үзләре янында калырга тәкъдим итә. Ильяс галәйһис-сәләәм өлкән яшьтәге бер хатынның өендә кунак ителә.

Бу хатынның авыру улы була. Хәзрәти Ильяс, ике рәкәгать намаз кылып, балага шифа бирүен сорап, Аллаһка дога кыла. Бала савыга һәм шуннан соң Ильяс галәйһис-сәләәм яныннан бер адым да китми. Ильяс галәйһис-сәләәмнән Тәүратны өйрәнә. Бу баланың исеме Әльясаг була.

Кыскасы, Ильяс галәйһис-сәләәм, үзеннән соң күркәм дан калдырып, бөек Раббысы белән кавыша. Ул илаһи рәхмәткә һәм хөрмәткә лаек була. Аның хакында аяти кәримәләрдә болай дип искә алына:

وَتَرَكْنَا عَلَيْهِ فِي الْآخِرِينَ سَلَامٌ عَلَىٰ إِلْ يَاسِينَ إِنَّا كَذَٰلِكَ
نَجْزِي الْمُحْسِنِينَ إِنَّهُ مِنْ عِبَادِنَا الْمُؤْمِنِينَ

**«Соңгылар арасында да аның турында (мактаулы сүзләр) калдырдык. Ильяска да сәлам булсын (дидек). Һичшиксез, игелек кылучыларга Без шулай әҗерләрен бирәбез. Чөнки, һичшиксез, ул (Ильяс) – Безнең инанган колларыбыздан»** («әс-Саффат», 129–132).

Ильяс галәйһис-сәләәмнең үлем фәрештәсе Газраилне күргәч куркып китүе риваять кылына. Газраил галәйһис-сәләәм, моның сәбәбен белергә теләп: «И, Аллаһның Пәйгамбәре! Үлемнән курыктыңмы?» – дип сорый. Ильяс галәйһис-сәләәм: «Юк! Үлемнән курыкканга түгел, дөнья тормышы белән хушлашканга күрә шушы хәлдә мин…» – дип җавап бирә. Аннары сүзен дәвам итә: «Дөнья тормышында Раббыма гыйбадәт кылып, игелекле эшләргә өндәп, яманлыклардан тыярга омтыла, вакытымны гыйбадәт һәм изге гамәл белән уздыра, күркәм әхлак белән яшәргә тырыша идем. Бу халәт мине

тынычландыра, күңелем шатлык һәм рухи рәхәтлек белән тула иде. Үлгәч, бу рәхәтлекләрне һәм ләззәтләрне башка татый алмаячагым һәм кыямәткәчә кабердә тотык булып калачагым өчен кайгырам!» – диде.

Галәйһис-сәләәм!..

Җәнабел-Хак барчабызга да дөньялыктагы тормышыбызны дөрес юлдан узып, Аңа якын булырга һәм фани, вакытлы ләззәтләргә алданмыйча, ахирәт бәхетенә лаек булырга насыйп итсен!

Амин!..

***Хәзрәти Ильяс галәйһис-сәләәм***





ХӘЗРӘТИ

# ӘЛЬЯСАГ

*галәйһиссәләм*

*Галәмнәрдән өстен кылынган*

# ХӘЗРӘТИ ӘЛЬЯСАГ

*галәйһис-сәләәм*

Әльясаг галәйһис-сәләәм – Бәни Исраил пәйгамбәрләреннән. Балачагында бик нык авырый һәм Ильяс галәйһис-сәләәмнең догасы бәрәкәтендә шифа таба. Шуннан соң Хәзрәти Ильястан бер адым да калмый йөреп, аңардан Тәүратны өйрәнә. Әльясаг галәйһис-сәләәм дә азгын Бәни Исраил кавемен төзәтү, яхшырту өчен күп көч куя. Кайчак аңа буйсыналар, вакыт-вакыт каршы чыгалар.

Әльясаг галәйһис-сәләәм Коръәни-Кәримнең ике аяти кәримәсендә телгә алына:

وَاذْكُرْ إِسْمَاعِيلَ وَالْيَسَعَ وَذَا الْكِفْلِ وَكُلٌّ مِنَ الْأَخْيَارِ

**«(И, Рәсүлем!) Исмәгыйльне, Әльясагны һәм Зүлкифлне дә искә ал. Һәммәсе дә хәерле кешеләрдән»** («Сад», 48).

Аяти кәримәдә **«искә ал»**, дип әмер бирелүе бу пәйгамбәрләрнең дә Аллаһ динен җәелдерү мәсьәләсендә хәлләреннән килгәнчә көч, фидакярлек, сабырлык һәм ныклык күрсәтүенә бәйле.

Әльясаг галәйһис-сәләәм искә алынган икенче аяти кәримә мондый:

وَإِسْمَاعِيلَ وَالْيَسَعَ وَيُونُسَ وَلُوطًا وَكُلًّا فَضَّلْنَا عَلَى الْعَالَمِينَ

**«Исмәгыйльне, Әльясагны, Юнысны һәм Лутны да (һидәят биреп, пәйгамбәр иттек). Барысын да галәмнәрдән өстен иттек»** («әл-Әнгам», 86).

Әльясаг галәйһис-сәләәмнең пәйгамбәрлек чорында кавемендәге кабиләләр арасында дәүләт белән җитәкчелек итү, идарәне кулга төшерү өчен ярыш башлана. Хәзрәти Әльясаг галәйһис-сәләәмне тыңламыйча, кабиләләр үзара дошманлык юлына баса. Соңсыз-хисапсыз фетнәләр, гауга-ызгышлар куба. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә аларга Ассирия дәүләте тарафыннан һөҗүм җибәрә. Нәтиҗәдә, Бәни Исраил кабиләләре үзләренең яман эшләре сәбәпле илаһи рәхмәттән ерагая һәм, ассириялеләргә җиңелеп, хурлыкка кала һәм пыран-заран китерелә.

Нишанҗызадә Мухйиддин Мәхмәд «Миръат әл-Кайнат» исемле китабында Әльясаг галәйһис-сәләәмнең могҗизалары турында сөйли:

Әриха шәһәрендәге халыкның эчәр суы әчеләнә. Кешеләр шундук Хәзрәти Әльясагка килеп, аннан ярдәм сорый. Ул исә, әчеләнгән суга бераз тоз кисәге ыргытып: «Тәмле бул!» – дип әйтә. Аллаһның рөхсәте белән су әүвәлгедән дә тәмлерәккә әйләнә.

Бурычлы бер тол хатынның Әльясаг галәйһис-сәләәм янына барганлыгы риваять кылына. Ул пәйгамбәргә үзенең бик фәкыйрьлеге турындап сөйли. Хәзрәти Әльясаг: «Өеңдә нәрсә бар?» – дип сорый Теге хатын: «Бер уч чамасы маем бар!» – ди. Әльясаг галәйһис-сәләәм: «Бар, шул майны берәр савыт эченә куй!» – дип боера. Тол хатын, өенә кайтып кушылганны эшләгәч, бөтен савытларның да май белән тулганлыгын күрә. Әлеге могҗиза ярдәмендә ул барлык бурычларын түли, шуннан соң да аның майлары бетми.

Үлеме якынлашкач, Әльясаг галәйһис-сәләәм Зүлкифл галәйһис-сәләәмне чакырып ала һәм, Аллаһның әмере белән, аны үзеннән соң эшен дәвам итүче итеп билгеләп куя.

Галәйһис-сәләәм!..



ХӘЗРӘТИ

# Зөлкифел

*галәйһиссәләм*

*Илаһи рәхмәткә чумган изге пәйгамбәр*

# ХӘЗРӘТИ ЗӨЛКИФЕЛ

*галәйһис-сәләәм*

Әльясаг галәйһис-сәләәмнең агасының улы Зөлкифел (Зүлкифл) дә Бәни Исраил пәйгамбәрләреннән була. Риваятьләргә күрә, чын исеме – Бишр. Зөлкифел кушаматы, Әльясаг галәйһис-сәләәмнән соң дин кушканнарны Исраил угылларына белдерү өчен җаваплылык алып, шул чордагы пәйгамбәрләрнең эшләрен башкарып, күп савапка лаек булганы өчен бирелә. Гарәп телендә «зү» ия булу, «кифл» сүзе исә җаваплылыкны үз өстенә алучы, Аллаһтан насыйп ителгән өлеш, микъдар, кат (тапкыр, мәртәбә) кебек мәгънәләр белдерә. Бу кушамат дөнья байлыкларын, аның микъдарын түгел, ә өстен кешелек сыйфатларын һәм ахирәттәге югары дәрәҗәләрне күздә тота.

Ибне Габбас радыйаллаһу ганһедән мондый риваять тапшырыла:

*«Аллаһ Тәгалә Исраил угыллары пәйгамбәрләреннән берсенә пәйгамбәрлек белән бергә мал-мөлкәт һәм хакимият тә бирә. Бу пәйгамбәрнең үлем сәгате якынайганда, Җәнабел-Хак аңа җанының алыначагын вәхи аша белдерә һәм: “Мал-мөлкәтне Исраил угыллары арасында төннәрен таң атканчы намаз укучы, көндезләрен ураза тотучы һәм кешеләр арасында кызып китмичә хөкем кылучы берәрсенә бир!” – дип боера.*

*Әлеге пәйгамбәр үзенә кушылганны Исраил угылларына җиткерә. Араларыннан бер яшь егет басып: “Бу эшкә мин җаваплы булырмын! Бу вазифага үзем алынам!” – ди. Пәйгамбәр ул егеткә: “Бу кавем эчендә синнән өлкәнрәкләр дә бар, син утырып тор әле!” – ди.*

*Аннары пәйгамбәр тәкъдимен икенче тапкыр кабатлый, теге егет янә: “Мин җаваплы булырмын”, – дип белдерә. Шул ук тәкъдим өченче мәртәбә кабатлангач та, тагын теге егет җавап бирә. Шуннан соң тәкъдимне әйткән пәйгамбәр үз урынына җаваплы итеп шул егетне калдырып, мөлкәтне аңа бирә. Бу егет Бишр була».*

Шайтан ул егеткә көнләшә. Яшь кеше үз өстенә алган вазифаны башкара алмасын өчен, төрле хәйләләр кора. Ләкин егет, иблис вәсвәсәләренә бирелмичә, үз өстенә алган әманәтне лаеклы саклап бара, Аллаһ юлында күп-күп тырышлык куя. Шуңа күрә аны «Зөлкифел» дип атыйлар.

Хәзрәти Зөлкифел турында Коръәни-Кәримдә ике аяти кәримә бар:

وَاذْكُرْ إِسْمَاعِيلَ وَالْيَسَعَ وَذَا الْكِفْلِ وَكُلٌّ مِنَ الْأَخْيَارِ

**«(И, Рәсүлем!) Исмәгыйльне, Әльясагны һәм Зүлкифлне дә искә ал. Һәммәсе дә хәерле кешеләрдән»** («Сад», 48).

وَإِسْمَاعِيلَ وَالْيَسَعَ وَيُونُسَ وَلُوطًا وَكُلًّا فَضَّلْنَا عَلَى الْعَالَمِينَ

**«Исмәгыйльне, Идрисне һәм Зүлкифлне дә (искә ал)! Аларның һәрберсе сабыр итүчеләрдән иде. Без аларны рәхмәтебезгә керттек. Һичшиксез, алар изге кешеләрдән иде»** («әл-Әнбия», 85–86).

Зөлкифел галәйһис-сәләәм дә Муса галәйһис-сәләәм шәригате белән гамәл кыла, кешеләргә Тәүратта кушылганнарны һәм тыелганнарны аңлата. Димәшкъ тирәләрендә вафат булганлыгы риваять кылына.

Галәйһис-сәләәм!..


ХӘЗРӘТИ
Локман
хәким
галәйһиссәләм

***Тышкы һәм эчке авыруларны дәвалау остасы, хикмәтле нәсыйхәтләре белән халык теленә кергән,***

# ХӘЗРӘТИ ЛОКМАН ХӘКИМ

***галәйһис-сәләәм***

Локман Хәким галәйһис-сәләәм пәйгамбәр яки әүлия була. Табиблар остазы, бу эшкә нигез салучы буларак билгеле. Хикмәт бирелгән затлардан булуы Коръәни-Кәримдә аның исеме белән аталган «Локман сүрәсе»ндә анык белдерелә:

وَلَقَدْ آتَيْنَا لُقْمَانَ الْحِكْمَةَ أَنِ اشْكُرْ لِلَّهِ وَمَنْ يَشْكُرْ فَإِنَّمَا يَشْكُرُ لِنَفْسِهِ وَمَنْ كَفَرَ فَإِنَّ اللَّهَ غَنِيٌّ حَمِيدٌ

**«Без Локманга хикмәтне “Аллаһка шөкер ит!” – дип бирдек. Кем дә кем шөкер итсә, үз файдасына шөкер иткән булыр, кем дә кем инкяр итсә, (белсен), һичшиксез, Аллаһ – Бай (һичнигә мохтаҗ түгел), Мактауга лаеклы»** («Локман», 12).

Шөкер итү колның аңа бирелгән нигъмәтләргә сөенүен, Раббысына төрле сүз һәм гамәлләр белән рәхмәт әйтүен белдерә. Шөкер – нигъмәтне аңлау-тану дигән сүз. Шул мәгънәгә нигезләнеп, ислам һәм иманны «шөкер итү» сүзе белән дә атыйлар.

Локман Хәкимнең нәсел-нәсәбе турындагы риваятьләр аның Әйюб галәйһис-сәләәм белән туган булуына ишарәли.[164] Ислам галимнәренең күпчелеге аны пәйгамбәр түгел, ә хикмәткә ия бер шәхес дип саный. «Хикмәт» сүзенең бер мәгънәсе теоретик гыйлемнәрне үзләштергәннән соң ирешелгән рухи камиллек ярдәмендә сүздә һәм эш-гамәлләрдә сизгерлек, алдан күрүчәнлек күнекмәсе барлыкка килүне белдерә. Аллаһ Тәгалә:

يُؤْتِي الْحِكْمَةَ مَنْ يَشَاءُ وَمَنْ يُؤْتَ الْحِكْمَةَ فَقَدْ أُوتِيَ خَيْرًا كَثِيرًا وَمَا يَذَّكَّرُ إِلَّا أُولُو الْأَلْبَابِ

**«Ул (Аллаһ) хикмәтне теләгәненә бирә. Кемгәдер хикмәт бирелгән икән, аңа бик зур игелек бирелгән. Әмма акыл ияләре генә фикер йөртә»**, – дип әйтә («әл-Бәкара», 269).

Хикмәт әйберләрнең асылын һәм серләрен аңлый белү дигән сүз. Бу исә йөрәктә илаһи нур чагылышы белән генә чынга аша ала.

Зәмахшәри Локман Хәкимнең хикмәт иясе булуын раслаган мондый вакыйганы бәян итә:

164. Карагыз: Сәләби, «Араис», 391 б.

Көннәрдән бер көнне Давыт галәйһис-сәләәм Локман Хәкимгә бер сарык суеп, иң яхшы урыныннан ике кисәк алып килергә куша. Локман Хәким суелган малның тел белән йөрәген китереп бирә. Берничә көннән Давыт галәйһис-сәләәм, янә бер сарык суеп, иң начар урыныннан ике кисәк ит алып килүен сорый. Локман Хәким монысында да тел белән йөрәкне китереп бирә. Хәзрәти Давыт бу хәлнең сәбәбен кызыксынып сорагач, Локман Хәким бик хикмәтле җавабын бирә: «Яхшы булган чакларында алардан да яхшысы, яман булган чакларында алардан да әшәкесе юк!..» (Зәмахшәри, «Кәшшаф», V, 18).

Габдуллаһ ибне Гомәр радыйаллаһу ганһүмәдән риваять кылынган бер хәдис-шәрифтә болай диелә:

*«Локман пәйгамбәр түгел, күп гыйбадәт кылучы зат була. Аллаһ Тәгалә аны гөнаһлардан саклый. Ул бик уйлана. Нык иманлы була. Аллаһ Тәгаләне ярата, Аллаһ Тәгалә дә аны сөя. Аллаһ Тәгалә аңа хикмәт насыйп итә»* (Куртуби, «Тәфсир», XIV, 59–60).

Имам Малик сөйләгәннәрдән: «Миңа килеп ирешкәнчә, Локман Хәкимнән: "Без синдә күргән бу (өстенлекнең үзенчәлеге) ни ул?" – дип сораганнар (Монда аның фазыйләтләрен күздә тотканнар). Ул: "Туры сүзлелек, әманәтне үтәү, мине кызыксындырмаган нәрсәне кире кагу һәм вәгъдәгә тугрылык", – дип җавап биргән» (Муватта, «Кәлам», 17).

Локман Хәкимнең хикмәтле сүзләре һәм улына биргән үгет-нәсыйхәтләре Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә аңлатыла:

وَإِذْ قَالَ لُقْمَانُ لِابْنِهِ وَهُوَ يَعِظُهُ يَا بُنَيَّ لَا تُشْرِكْ بِاللَّهِ إِنَّ الشِّرْكَ لَظُلْمٌ عَظِيمٌ

**«Менә Локман улына вәгазьләп әйтте: "И, улым! Аллаһка ширек кушма. Һичшиксез, ширек – бик зур золым (караңгылык)"»** («Локман», 13).

Чыннан да, бик зур золым булган ширек бәндәне мәңгелек җәһәннәмгә дучар итәр.

Локман Хәким нәсыйхәтен дәвам итә:

يَا بُنَيَّ إِنَّهَا إِنْ تَكُ مِثْقَالَ حَبَّةٍ مِنْ خَرْدَلٍ فَتَكُنْ فِي صَخْرَةٍ أَوْ
فِي السَّمَاوَاتِ أَوْ فِي الْأَرْضِ يَأْتِ بِهَا اللَّهُ إِنَّ اللَّهَ لَطِيفٌ خَبِيرٌ

**«И, улым! Һичшиксез, ул (кылган игелегең яки яманлыгың) хәрдәл бөртеге авырлыгында булса һәм бер кыя эчендә яки күкләрдә, яки җирдә булса, янә дә Аллаһ аны (синең каршыңа) китерәчәк. Һичшиксез, Аллаһ – Мәрхәмәт итүче (иң вак эшләрне дә күрүче), Хәбәрдар»** («Локман», 16).

Моңа охшаш башка бер бер аяти кәримәдә болай диелә:

فَمَنْ يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ خَيْرًا يَرَهُ ۝ وَمَنْ يَعْمَلْ مِثْقَالَ ذَرَّةٍ شَرًّا يَرَهُ

**«Кем дә кем зәррә авырлыгы кадәр генә игелек кыла, аны күрәчәк. Кем дә кем зәррә авырлыгы кадәр генә начарлык кыла, аны күрәчәк»** («әз-Зәлзәлә», 7–8).

Нәсыйхәтенең дәвамында Локман Хәким әйтә:

يَا بُنَيَّ أَقِمِ الصَّلَاةَ وَأْمُرْ بِالْمَعْرُوفِ وَانْهَ عَنِ الْمُنْكَرِ وَاصْبِرْ عَلَىٰ مَا أَصَابَكَ إِنَّ ذَٰلِكَ مِنْ عَزْمِ الْأُمُورِ

**«И, улым! Намаз укы, яхшы дип беленгән нәрсәне әмер ит, яхшы дип танылмаган нәрсәдән тый һәм сиңа килгән нәрсәләргә сабыр ит. Һичшиксез, бу – (бик ныклы карарлылык кирәклеге) билгеләнгән эшләрдән»** («Локман», 17).

Аяти кәримәдә намазга, әмри бил-мәгъруф вә нәһйи ганил-мүнкәр (яхшылыкка өндәү, яманлыктан тыю) әмеренә һәм сабырлыкка игътибар юнәлтелә.

Намаз – мөэминнең мигъраҗы. Ул коллык вазифасының иң мөһимнәреннән берсе булып тора. Намазны хәтта дошманга каршы сугыш вакытында да калдырмыйлар. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Үзенә сәҗдә кылучыларны: **«... Аларның йөзләрендәге билгеләре – сәҗдә эзе (бар)...»** – дип шатландыра («әл-Фәтх», 29). Башка бер аяти кәримәдә: **«...Сәҗдә ит һәм якынай!»**[165] – дип боера («әл-Галәкъ», 19)[24].

Сәхабәләрдән Габдуллаһ ибне Шыйххир радыйаллаһу ганһе Пәйгамбәр Әфәндебезнең намаздагы хошуг хәленә бәйле бер күренешне болай сурәтли: «Бер тапкыр Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына барган идем. Ул намаз укый, елаганга күрә күкрәгеннән кайнап торган казан тавышы кебек тавышлар чыга иде» (Әбү Давыт, «Салат», 156–157/904; Әхмәд, IV, 25, 26).

Әмри бил-мәгъруф вә нәһйи ганил-мүнкәр мөэминнең иң мөһим вазифаларыннан санала. Җәнабел-Хакның аңа биргән нигъмәтләрне, беренче чиратта иман һәм һидәятне, башкаларга да таратып, бу нигъмәтләргә шөкер итү вазифасын башкару дигән сүз ул. Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм шәхесе аша бу тәблигъ эшенең ысул-алымын менә болай белдереп куя:

فَبِمَا رَحْمَةٍ مِنَ اللّٰهِ لِنْتَ لَهُمْ وَلَوْ كُنْتَ فَظًّا غَلِيظَ الْقَلْبِ لَانْفَضُّوا مِنْ حَوْلِكَ فَاعْفُ عَنْهُمْ وَاسْتَغْفِرْ لَهُمْ وَشَاوِرْهُمْ فِي الْأَمْرِ فَإِذَا عَزَمْتَ فَتَوَكَّلْ عَلَى اللّٰهِ إِنَّ اللّٰهَ يُحِبُّ الْمُتَوَكِّلِينَ

**«Аллаһтан шәфкать белән син аларга йомшак булдың. Әгәр дә дорфа, каты күңелле булсаң, алар синең яннан таралып киткән булырлар иде.**

165. Сәҗдә аяте.

**Аларны кичер, алар өчен кичерү сора, эшләрдә алар белән киңәш. Әмма карарга килсәң, шунда ук Аллаһка тапшыр. Һичшиксез, Аллаһ тәвәккәл итүчеләрне сөя!»** («Әли Гыймран», 159).

Җәнабел-Хак хәерлегә өндәү ысулы белән бәйле рәвештә башка бер аяти кәримәдә:

ادْعُ إِلَىٰ سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ

**«(Рәсүлем!) Хикмәт белән һәм күркәм үгет белән Раббыңның юлына дәгъват ит!..»** – дип әйтә («ән-Нәхел», 125).

Сабырлыкка килгәндә, Коръәни-Кәримдә ул иң күп урын бирелгән темалардан. Сабырлыкның дөньялыктагы ягы бик ачы, бик авыр, ләкин ахирәт тарафы, ягъни әҗере бик татлы. Бөтен пәйгамбәрләр дә сабырлык фильтры аша узган. Җәнабел-Хак аяти кәримәдә:

وَبَشِّرِ الصَّابِرِينَ

**«...(И, Рәсүлем!) Сабыр итүчеләрне сөендер!»** – дип әйтә («әл-Бәкара», 155).

Габдуллаһ ибне Мугаффәл радыйаллаһу ганһе бәян кыла:

Бер кеше килде дә: «И, Аллаһның Рәсүле! Мин Сине яратам», – дип әйтте. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Ни әйткәнеңә игътибарлы бул!»* – диде. Теге кеше: «Валлаһи, мин Сине яратам!» – дип өч тапкыр кабатлады. Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм шуннан соң ул бәндәгә: *«Әгәр мине яратсаң, фәкыйрьлек өчен үзеңә бер көбә әзерлә, чөнки мине яратучыга фәкыйрьлек максатына барып җитә торган сәлдән тизрәк килә»,* – дип боерды (Тирмизи, «Зүһд», 36/2350). Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез бу сүзләре белән гүя: «Әгәр Аллаһ ризалыгы өчен мине яратасың икән, бәлаләргә, авырлыкларга, ярлылыкларга түзәргә хәзер һәм риза бул! Чөнки үзең сөйгәнеңә буйсыну мәхәббәтнең шарты булып тора!..» – дип әйтә.

Коръәни-Кәримдә Локман Хәкимнең нәсыйхәтләре болай дәвам итә:

وَلَا تُصَعِّرْ خَدَّكَ لِلنَّاسِ وَلَا تَمْشِ فِي الْأَرْضِ مَرَحًا إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ كُلَّ مُخْتَالٍ فَخُورٍ

**«Йөзеңне кешеләрдән чөермә, җирдә масаеп йөрмә. Һичшиксез, Аллаһ һәр масаеп йөргән, үзен яратучы кешене сөйми!»** («Локман», 18).

Масаючанлык, ягъни тәкәбберлек, үзеңә соклану тамыры – җәһәннәмгә тоташкан холык сыйфатлары. Әл-Кәбир (бөек) сыйфаты Хак Тәгаләгә генә хас. Иблиснең җәннәттән куылып, Аллаһ колларын адаштыру, хак юлдан тайпылдыру йөкләмәсен үз өстенә алуының сәбәбе Хәзрәти Адәмгә карата тәкәб-

берләнеп, Раббысына каршы баш күтәрүеннән гыйбарәт. Карун да, үзенә рухи гыйлемнәр бирелүенә карамастан, Хәзрәти Һарунга көнләшеп хөсетләнүе сәбәпле, һәлакәткә дучар ителә.

Хәзрәти Локман улына:

وَاقْصِدْ فِي مَشْيِكَ وَاغْضُضْ مِنْ صَوْتِكَ إِنَّ أَنْكَرَ الْأَصْوَاتِ لَصَوْتُ الْحَمِيرِ

**«Җир йөзендә урта юлны тот (бик тиз дә, бик акрын да йөрмә, тынычлыгыңны сакла), тавышыңны түбәнәйтә төш (кычкырып сөйләшмә). Һичшиксез, тавышларның иң яманы – ишәкләрнең тавышы»**, – дип киңәш бирә («Локман», 19).

Бу аяти кәримәләр мөэминнәрдә әдәплелек һәм ягымлылык тәрбияли. Нәзакәтсезлекне белдергән ишәк тавышы куәтле булып башланып, ахырга таба көчсезләнә. Сүз кирәксез урында һәм артык кычкырып яңгыратылган, ямьсез, күңелсез тавыш турында бара. Мондый формада мөрәҗәгать итү дә нәзакәтлелек кагыйдәләренә туры килми. Шуңа күрә дә аяти кәримәдә Җәнабел-Хак колларын нәзакәтле, ягымлы сөйләшергә өнди, ягъни кирәксез урында кычкырып сөйләшкән бәндә ишәккә охшар һәм ямьсез гамәл кылган булыр.

Хәсән әл-Басри Хәзрәтләре сөйләгәннәрдән: «Мөшрикләр тавышларының көчлелеге белән мактаналар иде. Аллаһ Тәгалә аларны: “Әгәр тавышның көче хәерле нәрсә булса, бу сыйфат белән ишәкне алардан өстен итәр идем!” – дип кисәтә». Бу дөньяда вак-төяк, әһәмиятсез нәрсә булып күренгән ягымлылык, нәзакәтлелекнең хисап көнендә бик зур роль уйнаячагы риваятьләрдә белдерелә. Шуңа күрә кирәксезгә сөйләшүдән аеруча тыелу мөһим, әйтелгән сүзләрнең мәгънәсе нинди нәтиҗәгә китерәчәген яхшылап уйларга кирәк. Хәдис-шәрифләрдә дә бу хакта анык әйтелә:

*«Кол яхшылап уйламыйча берәр нәрсә әйтеп ташлар да шул сәбәпле җәһәннәмнең көнчыгышы белән көнбатышы арасыннан ерак бер урынга эләгер»* (Бохари, «Рикак», 23).

*«Кол Аллаһка хуш килгән берәр сүз әйтер, ләкин шуның белән Аллаһның ризалыгына ирешәчәген уйлап та карамас. Хәлбуки, әнә шул сүз сәбәпле, Аллаһ Үзе белән очраштырачак кыямәт көненәчә ул заттан канәгать булыр. Башка бер кол Аллаһның ачуын китергән берәр сүз әйтер, тик ул сүзнең Аллаһ газабына илтәчәген һич уйламас. Ә Аллаһ әнә шул яман сүз сәбәпле ул затны Үзе белән очраштырачак кыямәт көненәчә газапка тотар»* (Тирмизи, «Зүһд», 12; Ибне Мәҗә, «Фитән», 12).

Локман Хәкимнең нәсыйхәтләре урын алган югарыдагы аяти кәримәләр арасында ике аяти кәримә өммәткә дөрес юнәлеш күрсәтү ягыннан бик мөһим. Риваятькә күрә, алар Сәгъд ибне Әби Вәкъкас радыйаллаһу ганһе белән аның әнисе белән бәйле рәвештә иңдерелә.

Хәзрәти Сәгъд радыйаллаһу ганһе анасына карата бик итагатьле бала була. Улы ислам кабул иткән вакытта, әнисе: «Әй, Сәгъд! Син нишләдең? Әгәр син бу яңа диннән баш тартмасаң, ант итәм, мин ашау-эчүдән туктап, үләчәкмен. Сине исә минем аркада “анасын үтерүче!” дип яман исем белән атаячаклар!» – дигән. Хәзрәти Сәгъд: «Алай эшләмә, әнием, мин барыбер бу диннән һичнәрсә өчен баш тартмам!» – дигәч, әнисе ике көн, ике төн ашамыйча, хәлсезләнә. Моны күргәч, Хәзрәти Сәгъд: «Әнием! Валлаһи, йөз җаның булып, алар бер-бер артлы чыкса да, мин бу диннән һич баш тартмам, белеп тор! Телисең икән – аша, телисең икән – ашама!..» – дип белдерә. Шуннан соң әнисе ашый башлый һәм шушы ике аять яки аларның икенчесе иңдерелә:

وَوَصَّيْنَا الْإِنْسَانَ بِوَالِدَيْهِ حَمَلَتْهُ أُمُّهُ وَهْنًا عَلَىٰ وَهْنٍ وَفِصَالُهُ فِي عَامَيْنِ أَنِ اشْكُرْ لِي وَلِوَالِدَيْكَ
إِلَيَّ الْمَصِيرُ وَإِنْ جَاهَدَاكَ عَلَىٰ أَنْ تُشْرِكَ بِي مَا لَيْسَ لَكَ بِهِ عِلْمٌ فَلَا تُطِعْهُمَا وَصَاحِبْهُمَا
فِي الدُّنْيَا مَعْرُوفًا وَاتَّبِعْ سَبِيلَ مَنْ أَنَابَ إِلَيَّ ثُمَّ إِلَيَّ مَرْجِعُكُمْ فَأُنَبِّئُكُمْ بِمَا كُنْتُمْ تَعْمَلُونَ

**«Без кешегә ата-анасына игелек кылырга васыять иттек. Анасы аны зәгыйфьлек өстенә зәгыйфьлек белән йөрткән. Аны имүдән аеруы исә ике ел эчендә. (әнә шуңа күрә) Миңа һәм ата-анаңа шөкер кыл, чөнки кайту – Миңа. Әмма (шул ук вакытта) ул икәү синең бернинди гыйлемең булмаган нәрсәләрне Миңа ширек кылуың өчен сине көчли калсалар, аларга итагать итмә. Әмма дөньяда ул икәү белән яхшы күрелгән рәвештә бергә бул. Ләкин син Миңа юнәлгәннәрнең юлына ияр. Соңыннан кайтуыгыз Миңа, Мин исә сезгә ни кылганнарыгызны хәбәр итәчәкмен»** («Локман», 14–15) (Мөслим, «Фәдаилүс-Сахабә», 43–44; Ибне Әсир, «Үсдул-Габә», II т., 368 б.).

Әбү Умамә радыйаллаһу ганһе риваятенә күрә, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

*«Локман улына: “Галимнәрнең мәҗлесләрендә катнаш! Гыйлем ияләренең сөйләгәннәрен тыңла! Чөнки Аллаһ Үзе яудырган мул яңгыр белән үле туфракны терелткән кебек, үле йөрәкне дә хикмәт нуры белән терелтер”, – дип әйткән»* (Хәйсәми, «Мәҗмагуз-Зәваид», I, 125).

Локман Хәким бер нәсыйхәтендә мондый киңәшләр биргән:

«Мин күп кенә пәйгамбәрләргә хезмәт иттем. Аларның әйткәннәреннән кыскача сигез хөкемне сайлап алдым. Әгәр игътибар белән шул сигез шартны үтәсәң, газаптан котылырсың:

1. Намазда чакта – йөрәгеңне;
2. Кешеләр арасында чакта – телеңне;
3. Табында – кулыңны;
4. Башка кеше өендә чакта, күзеңне сакла.

Калган дүрт нәрсәнең икесен һәрвакыт истә тотарга, икесен исә онытырга кирәк.

Һәр халәттә дә син истә тотарга тиеш икенең берсе – Аллаһ Тәгалә. Аны күп-күп зикер кыл! Икенчесе исә – үлем, аның турында да һичкайчан онытма!

Онытылырга тиеш икенең берсе – башкасына кылган игелекләрең, икенчесе исә – башкаларның сиңа карата кылган яманлыклары. Боларны шундук оныт!..

Локман Хәкимнең ышанычлы китапларда тапшырылган кайбер нәсыйхәтләре:

«И, улым! Тәкъвалыкны үзеңнең ахирәт өчен туплана торган капиталыңа әйләндер! Чөнки тәкъвалык – мал-мөлкәтсез башкарыла торган сәүдә ул!»

«И, улым! Җеназада катнаш! Чөнки җеназа сиңа ахирәтне искә төшерер. Хәрәм эшләр һәм гөнаһлар исә синең дөньяга тартылуыңны арттырыр».

«И, улым! Ялган сөйләүченең нуры качар. Яман холыклы бәндәнең кайгы-борчулары күбәер».

«И, улым! Тиле затка берәр мәсьәләне аңлату – авыр ташны урыныннан кузгатуга караганда кыенрак».

«И, улым! Наданны кая да булса илче итеп җибәрмә! Әгәр акыллы һәм хикмәт иясе берәр кешене тапмасаң, үзең бар!»

«И, улым! Дөнья ул тирән диңгез кебек. Бик күпләр анда батып үлделәр. Көймәң – тәкъвалык, канәгатьлек, йөгең – иман, халәтең – буйсыну, азыгың изге гамәл булсын. Котыласың икән, бу – Аллаһ Тәгалә рәхмәте белән, батасың икән – гөнаһың сәбәпле».

«И, улым! Әтәч синнән акыллырак булмасын! Ул һәр иртә зикер һәм тәсбих әйтә, ә син йоклыйсың!»

«Ашказаны тулса, фикерләү йокыга талыр. Әгъзалар да гыйбадәткә соңарыр!»

«И, улым! Шундый дуслар сайла, юлларыгыз аерылган чакта, син дә аларны, алар да сине сөйләп йөрерлек булмасын!»

«Дусларыңны сакла! Якыннарыңны зиярәт кыл!»

«И, улым! Өч нәрсә өч нәрсә белән беленә: түземлек – газап килгәндә, кыюлык – яу кырында, ә туганлык – мохтаҗлык вакытында»

«Гөнаһлардан кала, (башка эштә) дусларың яклы бул!»

«И, улым! Ничек инде кешеләр вәгъдә ителгән газаптан курыкмыйча, һәр көн гыйбадәт һәм тәгатькә игътибарсыз булырлар!»

«И, улым! Дөньядан җитәрлек кадәрен ал, аңа бирелмә, югыйсә бу – ахирәтеңә зыян китерер. Дөньядан тулысынча да ваз кичмә, югыйсә кешеләр өчен йөккә әйләнерсең. Ураза тот, ул шәһвәтне тыя. Ләкин сине намаздан аерырлык дәрәҗәдә күп ураза тотма! Чөнки Аллаһ катында намаз уразадан зуррак».

«И, улым! Игелекне аны аңлаган кешегә кыл. Сарык белән бүре арасында дуслык булмаган кебек, яхшы белән яман арасында да дуслык булмас. Бәхәс, ызгыш яратучы хурлыкка калыр; әшәкелекләр булган урынга баручы шик астына эләгер; яман нәрсәгә якынаючы үзен коткара алмас, телен тыеп тормаган үкенер».

«Яхшыларга хезмәт ит, тик яманнар белән дуслык корма!»

«И, улым! Ышаныч кеше булсаң, баерсың. Йөрәгең гөнаһ таплары белән тулган килеш, кешеләргә Аллаһтан куркучы булып кыланма».

«Үзең турында онытып, кешеләрне игелеккә өндәмә! Югыйсә синең хәлең, кешеләргә яктыртканда, үзе янып бетә торган шәмгә охшап калыр!»

«И, улым! Бала чагыңда әдәпле булсаң, өлкәнәйгәч файдасын күрерсең!»

«Вак-төяк эшләрне читкә какма! Чөнки кечкенә нәрсә иртәгә зурга әйләнер».

«И, улым! Күңелеңне борчу-кайгылар белән тутырма. Ачкүзлелектән саклан. Тәкъдиргә риза бул. Аллаһ тарафыннан сиңа бирелгәнгә канәгатьлек белдер һәм тормышың матурлансын, күңелең шатлык белән тулсын, тормыштан тәм табарсың».

«И, улым! Дөнья тормышы кыска ул. Синең андагы гомерең тагын да кыскарак. Бу кыска гомернең аз гына бер өлеше калган».

Рәсүл Әкрәм салләллаһу галәйһи вә сәлләм Локман Хәким турында искә алып, болай дигән:

*«Локман улына: “Аллаһ Тәгалә үзенә әманәт ителгән нәрсәне саклар! Мин дә сине, малыңны, динеңне һәм гамәлеңнең ахырын Аллаһ Тәгаләгә әманәт итәм!” – дип әйтә»* (Ибне Ханбәл, II, 87). Риваятькә күрә, Локман Хәкимнең йөзек кашында: «Күргән нәрсәне яшерүең шөбһәләнгән нәрсәңне ачып бирүгә караганда хәерлерәк!» – дип язылган була.

Галәйһис-сәләәм!..

# ХӘМЕДҺӘМ ШӨКЕР

**«Без Локманга хикмәтне «Аллаһка шөкер ит!» – дип бирдек. Кем дә кем шөкер итсә, үз файдасына шөкер иткән булыр, кем дә кем инкяр итсә, (белсен), һичшиксез, Аллаһ – Бай (һичнигә мохтаҗ түгел), Мактауга лаеклы»** («Локман», 12).

Аллаһ каршында коллык таләп иткән гамәлләрнең иң әһәмиятлеләреннән берсе – хәмед һәм шөкер. Бу шарт Коръәни-Кәримнең тәүге аяти кәримәсендә үк белдереп куелган:

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ

**«Барча мактаулар – галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһка!»**

Җәнабел-Хакның илаһи сәнгатендә һәм сыйфатларында чагылыш тапкан чиксез бөеклеген мактау – «хәмед»; Аның чиксез шәфкатенә һәм сый-нигъмәтләренә тел, гамәл һәм йөрәк белән мактау-данлаулар, рәхмәт белдерү «шөкер» була. Бу ике сүз мәгънә ягыннан бер-берсенә бик якын.

Чыннан да, мәхлукларның иң гадиеннән иң камиленә кадәр төзелгән иерархиядә иң югары урынны биләгән кешенең шул рәвешле «әшрәфи мәхлукат» (мәхлукларның иң хөрмәтлесе) булуына бәйле табигый таләпне хасил иткән «хәмед һәм шөкер» диннең иң тирән һәм иң мөһим мәсьәләләреннән гыйбарәт.

Яратылышындагы сафлык һәм затлылыкны саклаган кеше үзенә бер чынаяк су бирүчегә дә күңелендә рәхмәт хисе тоя. Димәк, барлык нигъмәтләрнең чыганагы һәм аларны тәкъдим итүче булган Раббысына карата адәм баласының рәхмәтсез мөнәсәбәте акылга да, намуска да каршы килә. Бу бары тик зиһен зәгыйфьлеге һәм хис-тойгылар салкынлыгы нәтиҗәсе генә була ала.

Кәләш бүлмәсе кебек тәфсилләп, матурлап бизәлгән, кеше аңы һәм аның зәвыгы җиткән чикне күп тапкыр узып киткән бу җиһанның хисапсыз илаһи кодрәт чагылышын күрсәткән атомнар, молекулалар, мең дә бер исле һәм төсле чәчәкләрнең һәм җимешләрнең, иң сөеклесеннән иң вәхшиенә кадәр төрле хайваннарның һәм бөтен предметларның холык-рәвешләренә күрә гаҗәеп тәртипкә салынуы – камил иҗат әсәре булган кешенең коллык вазифасын тиешенчә башкарылуы өчен.

Чын мөэмин акыл һәм намус белән илаһи коллыкны аңлап яшәргә тырышучы фазыйләтле кеше була. Тиешенчә шөкер итүче бер кол булырга теләгәннәр нигъмәтләрне тану-аңлау белән генә канәгатьләнә алмый. Чын нигъмәт иясен таныганнан соң, Аның каршындагы вазифаларны үтәү кирәклеген дә

аңлау мөһим, чөнки нигъмәтләрнең шушы рәвешле Аллаһка бәйләп каралуы кешеләрне Аңа омтылыш, йөрәкләрне мәгърифәт һәм мәхәббәт белән сугару ягыннан бик нәтиҗәле чараны тәшкил итә.

Һичшиксез, галәмдә Аллаһны мактап тәсбих әйтмәгән бер генә атом, бер генә молекула да юк. Хәтта хайваннар да тәсбих-доганың ни икәнен яхшы белә. Кешедән кала башка мәхлукларның ихтыярсыз рәвештә кылган тәсбихен «аңсыз тәсбих» дип атыйлар. Аларны бары саф, ачык йөрәкле кешеләр генә тоя ала. Кеше исә мәхлуклар чылбырында иң камиле булганга күрә, аның хәмед-шөкерләренең дә мөкәммәллеге бу дәрәҗәсенә туры килергә тиеш. Шөкер ителергә тиеш булып та, моны башкаруда безнең тарафтан гафиллек күрсәтелгән нигъмәтләр чынлыкта берәр төрле авырлыкка, чыгымга әйләнә. Андый гафиллектән калган утырым, тап исә, гөнаһка әверелә.

Нигъмәт иясен танып шөкер кылу һәр колның төп вазифасы булып тора. Ә нигъмәт ни соң ул? Аның үлчәмнәрен Коръән нуры һәм аның гыйлемнәре билгели. Коръәни-Кәрим безгә нигъмәтләрнең асыл сыйфатларын да белдерә. Дөньяның хикмәтләрен һәм кешенең асылын төшенү бары шөкер итү белән генә чынга аша ала. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Коръәни-Кәримдә:

وَلَقَدْ آتَيْنَا لُقْمَانَ الْحِكْمَةَ أَنِ اشْكُرْ لِلَّهِ

**«Без Локманга хикмәтне "Аллаһка шөкер ит!", – дип бирдек...»** – дип әйтә («Локман», 12).

Аяти кәримәгә ярашлы рәвештә, шөкер итүчегә хикмәтләр һәм серләр дөньясының асылы күрсәтелә, өстәвенә мондый мөмкинлекнең шөкер итүен дәвамлы кылган өчен бирелгәнлеге әйтелә.

Җәнабел-Хак ихтыяры бу дөньяда дүрт төрле рәвештә чагылыш таба:

1. Аның рәхмәте;
2. Аның ачуы, каһәре;
3. Рәхмәт булып күренгән каһәре;
4. Ачу, каһәр булып күренгән рәхмәте.

Вакыйгаларга предметның тышкы чагылышын гына күрсәткән күзге кебек карасалар, аларның тышкы рәвешен генә күреп, кешеләр күп очракта ялгыша. Ләкин акылны илаһи вәхи белән тәрбияләп, аның көче җитмәгән урында әйтерсең рентген кебек сәламәт йөрәк белән карый белүчеләр хикмәтне аңлау бәрәкәте аша бик күп авырлыклардан һәм газаплардан котылуга ирешә. Коръәни-Кәримдә:

كُتِبَ عَلَيْكُمُ الْقِتَالُ وَهُوَ كُرْهٌ لَكُمْ وَعَسَىٰ أَنْ تَكْرَهُوا شَيْئًا وَهُوَ خَيْرٌ لَكُمْ
وَعَسَىٰ أَنْ تُحِبُّوا شَيْئًا وَهُوَ شَرٌّ لَكُمْ وَاللَّهُ يَعْلَمُ وَأَنْتُمْ لَا تَعْلَمُونَ

**«...Сез нәрсәне дә булса сөймәскә мөмкин, әмма ул – сезнең өчен яхшылык. Сез нәрсәне дә булса сөяргә мөмкин, әмма ул – сезнең өчен начарлык! Аллаһ белә, сез исә белмисез»**, – дип хәбәр иткән аяти кәримә («әл-Бәкара», 216) белән илаһи җәза булып күренгән Аллаһ рәхмәтенә һәм илаһи рәхмәт булып чынга ашкан Аллаһ каһәренә ишарәләнә.

Икенче яктан караганда, аң-зиһенне үстереп, күңелне яхшыртып, югары күтәрелгән саен, «нигъмәт» төшенчәсе дә үзгәрә һәм бәндә гомум гавам ирешә алмаслык камиллек дәрәҗәсен яулый. Шулчакта кеше хәтта илаһи җәза күренешләрендә дә, шартына күрә, берәр кисәтү яки нәфескә чикләрен күрсәткән берәр хикмәт чагылышы һ.б. булганын аңлый. Хаҗи Бәйрәм Вәлинең түбәндәге шигырь юллары шул хакта:

«Хуш миңа Синнән килгәннәр,

Әле ачылмаган чәчәк йә энә булса да».

Мондый рухи дәрәҗәгә ирешкән мөэмин өчен һәр күренеш шөкер һәм хәмед-сәнәләр таләп итә торган бер нигъмәт дип саналыр. Кешеләрнең гомуми, гавами өлеше, аң-зиһеннәренә нисбәтле рәвештә, җәза эченә яшеренгән илаһи рәхмәтне яки рәхим-шәфкать эчендәге илаһи каһәрне вакытлар узгач кына күрә ала. Ә нәфесләрен тәрбияләү нәтиҗәсендә үзләренә хикмәт бирелгән затлар моны баштан ук күрә һәм аңлый. Шунлыктан кешеләрнең гавами өлешенә турыдан-туры йөкләнгән вазифа нигъмәт күренеше вакытында шөкер итү, илаһи ачу күренеше каршында сабырлык күрсәтүдән гыйбарәт, ә хикмәт ияләре югарыда искә алынган дүрт төрле күренешкә дә бер үк төрле халәттә кала. Аларның Раббыга карата мөнәсәбәтләре үзгәрми, чөнки илаһи газап вакытында да Аллаһны мактау-данлаудан туктамау тагын да көчлерәк җәзалардан саклау гына түгел, моның илаһи рәхмәткә әйләнүенә дә бер сәбәп була. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм илаһи кодрәт чагылган һәр күренештә:

اَلْحَمْدُ لِلّٰهِ عَلٰى كُلِّ حَالٍ

*«Һәр очракта да Аллаһка мактаулар булсын!»* – дип зикер әйтергә киңәш биргән һәм шуңа өндәгән. Бу халәтне саклый алмаганнар гафләтләре сәбәпле тәкъдиргә каршы үзенә күрә сугыш игълан иткән санала.

Шөкер һәм хәмед-сәнәләрне теләсә нинди авыр хәлдә дә туктатмыйча, уңышка ирешә алганнар бу дин кешеләргә вәгъдә иткән хозурлыкның иң югары ноктасына күтәрелә. Мөэмин йөрәкләр әнә шул ноктага ирешү нисбәтендә тынычлыкка һәм хозурлыкка тиенә.

Илаһи каһәр булып күренгән рәхмәткә үрнәк сыйфатында Хәзрәти Ягъкуб белән Хәзрәти Йосыфка узарга туры килгән күренешләр бик гыйбрәтле. Һәр мизгелдә Хак Тәгалә белән бергә булу серен аңлап, дөньялык белән бәй-

ләнешләре тулысынча өзелсен, шул рәвешле югары дәрәҗәләргә ирешсеннәр өчен, Аллаһ Җәллә Җәләлүһү аларга бик зур кайгы, көчле сагыш, аерылу газабы, төрле кыенлыклар, түземлек таләп иткән сынаулар җибәрә. Аларның чит җирләрдә, бер-берсеннән еракта яшәп ирешкән камиллекләре нәтиҗәсендә, Хәзрәти Ягъкуб белән Хәзрәти Йосыфның тормышы Коръәни-Кәримдә «кыйссаларның иң матуры» дип тәкъдим ителә.

Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Ходайбия килешүе әсхабе кирамга башта җиңелү, ягъни аларга җибәрелгән илаһи җәза булып күренә. Ләкин бу килешүдән соң бер-бер артлы агылган мең дә бер нигъмәт һәм җиңү капкаларының ачылуы әлеге вакыйганың никадәр зур илаһи рәхмәт икәнлеген күпмедер вакыт узгач күрсәтә. Ходайбия килешүеннән соң ике ел эчендә мөселманнар саны исламның тарала башлавыннан шул көнгә кадәр узган унтугыз елда мөселманлык кабул иткәннәр санынннан күп тапкыр арта. Өстәвенә Мәккәи Мөкәррәмә дә кан коелмыйча гына яулап алына.

Илаһи рәхмәт булып күренгән җәзага килгәндә, Һуд галәйһис-сәләәм кавеме – Гад кавеме очрагы моның бик ачык мисалы. Алар үзләренә газап итеп җибәрелеп, күк йөзен каплап алган болытларны күргәч, пәйгамбәрләрен мыскыл итеп: «Син газап турында сөйлисең, ә чынлыкта яңгыр гына явачак!» – дия-дия, үз-үзләрен алдыйлар. Ләкин яңгыр яумый, бу азгын кавем исә һәрнәрсәнең астын-өскә китергән коточкыч давыл белән һәлак ителә.

Дөнья нигъмәтләренә алданып, аларны мәңгелек дип уйлап, ахирәт тормышларын җимергән гафил бәндәләр өчен бу фани галәм үзе үк нәтиҗәсе мәхшәрдә ачыкланачак илаһи газаптан гыйбарәт. Бу дөньяны үзләренә бирелгән бер җәннәт дип санаучы күпме бәдбәхетнең ачы язмышы Изге Китапта ап-ачык сурәтләп бирелә.

Берәр бай кешенең мал-мөлкәте аның үзенә бер илаһи рәхмәт булып күренә. Тик Аллаһ юлында сарыф ителмәсә, әлеге байлык кыямәт көнендә илаһи газапка әйләнеп, хуҗасын хәсрәткә батырачак.

Аллаһ рәхмәте һәм җәзасы арасында бәргәләнгән бу дөнья турында илаһи хикмәткә ия йөрәкле күренекле затлар бик матур әйткән:

«Бу дөнья акыллылар өчен – сәйри бәдайидән (илаһи кодрәт бизәкләрен йөрәк белән күзәтү), ахмаклар өчен ашау һәм шәһвәттән гыйбарәт».

Колларының кулында ни генә булса да, асылда ул – Аллаһныкы. Табигатьтән һәм кешеләрдән килгән һәртөрле нигъмәтнең чын хуҗасы – аларны яраткан Халикъ Тәгалә. Сәламәт йөрәк бу хакыйкатьне аңларга тиеш. Мәхлуклар бер арадашчы, корал булып тора, чөнки һәр мәхлукка билгеле бер вазифаны үтәү йөкләнә. Нигъмәтне тарату эшендә барлык арадашчылар эшче һәм хезмәткәр булып тора. Нигъмәтнең чын хуҗасы һәм аны бирүче – галәмнәрнең Раббысы. Шуңа күрә һәр мөэмин нигъмәтне алып килүчедән бигрәк аны җибәрүчегә рәхмәт хисләре тоеп, шөкрана хисе белән тулы гомер кичерергә

бурычлы. Нигъмәтләрне безгә китергән сәбәпләргә һәм кешеләргә якынлык тоеп, нигъмәтнең хуҗасын оныту кешелек рухына каршы килә. Ләкин алып килүче мәхлукка, ягъни бу нигъмәтнең килүенә сәбәп булучыга рәхмәт әйтү дә әхлак һәм нәзакәтлелек шарты булып тора. Хәдис-шәрифтә: *«Үзенә карата игелек кылынган зат моны эшләүчегә: “Аллаһ сиңа хәерлесен бирсен!” – дип дога кылса, шөкер итү бурычын бик күркәм рәвештә үтәгән булыр...»* – дип әйтелә (Тирмизи, «Бирр», 87/2035).

Моның киресе буларак, нигъмәтнең чын хуҗасын онытып, бары тик кассир, курьер яки арадашчы сыйфатындагы фани затларга рәхмәтле булу көлке дә, урынсыз да. Аллаһ кануннарына ярашлы рәвештә, галәмдә һәрнәрсә ниндидер бер сәбәпкә бәйләнгән. Тик сәбәпләргә игътибар юнәлтеп, ул сәбәпләрне Яралтучы турында онытырга ярамый.

Җәнабел-Хак колларын күркәм рәвештә кисәтеп куя:

وَاللّٰهُ أَخْرَجَكُمْ مِنْ بُطُونِ أُمَّهَاتِكُمْ لَا تَعْلَمُونَ شَيْئًا وَجَعَلَ
لَكُمُ السَّمْعَ وَالْأَبْصَارَ وَالْأَفْئِدَةَ لَعَلَّكُمْ تَشْكُرُونَ

**«Аллаһ сезне берни белмәгән хәлегездә аналарыгызның карыннарыннан чыгарды, сезгә колаклар, күзләр һәм күңелләр бирде. Бәлки, сез шөкер итәрсез»** («ән-Нәхел», 78).

Җәнабел-Хакка шөкер итү вазифасы өч төрле башкарыла:

1. Тел белән шөкер итү. Иң түбән дәрәҗәдәге шөкер итү күренеше. Сүз кешеләрнең Яралтучыга карата тел белән: «Йә, Раббы! Сиңа чиксез рәхмәт-шөкерләр булсын!» кебек җөмләләр кулланып шөкер кылуы турында бара. Коръәни-Кәримдә:

وَأَمَّا بِنِعْمَةِ رَبِّكَ فَحَدِّثْ

**«Раббыңның нигъмәте турында сөйлә!»** – дип кушылса да («əд-Духа», 11), ни кызганыч, үле йөрәклеләр, авыру һәм гафил йөрәк ияләре Яралтучының нигъмәтләреннән хайвани комсызлык белән файдаланалар, тик Аллаһның исемен хәтта хайваннар кадәр дә зикер кылмыйлар. Алар аяти кәримәләрдә «әсфәли-сафилин – түбәннәрнең иң түбәне» һәм «бәл һүм әдалл – хайваннан да түбәнрәк» рәвешендә белдерелгән хәлгә төшәләр.

2. Гамәл белән шөкер итү. Аллаһ биргән нигъмәтләрне Аның юлында Ул кушканча сарыф итү дигән сүз. Бу күзлектән караганда, байлыкның шөкере инфак кылудан; гыйлемнең шөкере игелек кылу һәм башкаларны укытудан; тәннең шөкере исә һәр әгъзаны шәригатькә ярашлы рәвештә Хак Тәгалә юлында куллланудан гыйбарәт.

3. Йөрәк белән шөкер итү. Яралтучыга мәхәббәт һәм мәгърифәт белән якынаеп, һәр хәлеңә риза булу.

Чынлыкта, Аллаһның нигъмәтләренә лаеклы рәвештә шөкер итү мөмкин түгел. Кешенең көче-хәле моңа җитә алмый. Хәтта бөтен пәйгамбәрләр дә, тиешле дәрәҗәдә шөкер итә алмаганлыкларына күрә, һәрдаим тәүбә кылып яшәгәннәр. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: *«Мин көненә йөз тапкыр истигъфар кылам...»* – дип әйткән (Мөслим, «Зикер», 42). Ә без тиешле дәрәҗәдә шөкер итә алмаганыбыз өчен көндә ничә мәртәбә гафу сорарга тиешбез!?

Башка күзлектән караганда, хәмед-сәнә һәм шөкер кыла алу да Раббының олуг рәхмәте һәм бүләге, ягъни үзе бер нигъмәт булып тора. Бу логик эзлеклелекне чиксез дәвам итсәк, һәр шөкернең аны уңышлы кылу сәбәпле, яңа бер шөкер бурычы хасил итүен һәм бу бер-бер артлы килгән шөкер мөмкинлеген насыйп кылган Җәнабел-Хак каршында, бу чылбырның ахырына җитеп, шөкер бурычыннан котылуыбыз мөмкин түгел! Әнә шуңа күрә тулы, камил мәгънәсендә кабул ителгән шөкер итү бурычын үтәүдә бөтен кешелек, шул исәптән хәтта пәйгамбәрләр дә гаҗиз, көчсез.

Әлеге мәсьәләдә безгә йөкләнгән вазифа Аллаһның нигъмәтләрен тиешенчә танып, аңлап, болар өчен тиешле дәрәҗәдә шөкер итү хәлебездән килмәгәнлеген кабул итеп, кулыбыздан килгәнчә хәмед-сәнәләр әйтергә, көчебез җиткән хәтле шөкер итәргә тырышудан гыйбарәт. «*Нәфесен белүче Раббыны белә...*»[166] дигән хикмәтле хәдис Раббыны тануның нәфестә чагылыш тапкан илаһи сәнгать һәм нигъмәт каршында үзеңнең гаҗизлегеңне төшенү белән бәйле икәнен белдерә.

Нигъмәтләр чиксез, телләр көчсез, бәдәннәребез зәгыйфь… Иң зур нигъмәтләрнең берсе ул нигъмәтләрнең хуҗасын онытмаудан гыйбарәт. Нигъмәтләргә шөкер ул нигъмәтләрнең артуына нигез булган кебек, рәхмәтсезлек исә аларны азаюына сәбәп хасил итәр.

Шөкрана – җәннәт өчен капитал ул; рәхмәтсезлек исә – җәһәннәмгә керү документы. Рәхмәтсезлек көферлек нигъмәтен формалаштыра, ягъни Аллаһны тиләләрчә кире кагу дигән сүз. Мәсәлән, зәкяте бирелмәгәнгә күрә, гамәли шөкере башкарылмаган мал-мөлкәт, нигъмәт булудан туктап, фетнәгә әйләнә. Хуҗасы өчен авырлык китерәчәк бер сәбәп хасил итә. Җәнабел-Хак: **«Аларны (Аллаһ юлында сарыф итмәгән кешеләрне) тилмерткеч бер газап белән “сөендер”!»** – дип боера («әт-Тәүбә», 34).

Аллаһ Җәллә Җәләлүһү аяти кәримәләрдә тагын болай ди:

ثُمَّ لَتُسْأَلُنَّ يَوْمَئِذٍ عَنِ النَّعِيمِ

**«Шуннан соң сез ул көнне (сезгә бирелгән) нигъмәтләрдән соралачаксыз!»** («әт-Тәкәсүр», 8).

وَإِذْ تَأَذَّنَ رَبُّكُمْ لَئِنْ شَكَرْتُمْ لَأَزِيدَنَّكُمْ وَلَئِنْ كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ

166. Карагыз: Аҗлуни, «Кәшфүл-Хафа», II, 361.

**«...«Әгәр (нигъмәтләремә) шөкер итсәгез, һичшиксез, сезгә арттырачакмын. Әгәр рәхмәтле булмасагыз, һичшиксез, Минем газабым бик каты»** («Ибраһим», 7).

فَاذْكُرُونِي أَذْكُرْكُمْ وَاشْكُرُوا لِي وَلَا تَكْفُرُونِ

**«Мине искә алыгыз, Мин дә сезне искә алырмын. Миңа шөкер итегез, Миңа карата шөкерсез булмагыз!»** («әл-Бәкара», 152).

وَلَقَدْ آتَيْنَا لُقْمَانَ الْحِكْمَةَ أَنِ اشْكُرْ لِلَّهِ وَمَنْ يَشْكُرْ فَإِنَّمَا يَشْكُرُ لِنَفْسِهِ وَمَنْ كَفَرَ فَإِنَّ اللَّهَ غَنِيٌّ حَمِيدٌ

**«...Кем дә кем шөкер итсә, үз файдасына шөкер иткән булыр, кем дә кем инкяр итсә, (белсен), һичшиксез, Аллаһ – Бай (һичнигә мохтаҗ түгел), Мактауга лаеклы»** («Локман», 12).

Үзенә бирелгән нигъмәтләргә җавап итеп шөкрана кылуы һәр кешенең иң мөһим коллык вазифасы булып тора. Моны аңлаганнан соң, мөэмин шөкерсез һәм хәмед-сәнәләрсез яши алмый. Яралтучының нигъмәтләренә шөкраналы мөнәсәбәт мөэмин өчен иман байлыгының яртысын тәшкил итә. Хәдис-шәрифтә дә: *«Шөкер – иманның яртысы...»* – дип әйтелә. (Суюти, «Әл-Җәмигъ әс-Сагыйр», I, 107).

Камил акылга ия бәндә рухи һәм дини яктан өстен сыйфатларга ия изге затларга ак көнләшү белән кызыгып, алар кебек булырга тырышлык куярга тиеш. Матди яктан исә үзеннән түбәнрәк хәлдәгеләргә карап шөкер кылу кирәк.

Әүвәл пәйгамбәрләр, аннары әүлиялар һәм галимнәр шөкерне даими халәт, аерылгысыз гадәткә әйләндергәннәр. Коръәни-Кәримдә Нух галәйһис-сәләәм турында:

إِنَّهُ كَانَ عَبْدًا شَكُورًا

**«...Һичшиксез, ул бик күп шөкер кылучы бер кол иде!»** – дип әйтелә («әл-Исра», 3).

Ибраһим галәйһис-сәләәм турында болай искә алына:

شَاكِرًا لِأَنْعُمِهِ اجْتَبَاهُ وَهَدَاهُ إِلَىٰ صِرَاطٍ مُسْتَقِيمٍ

**«Ул Аның (Раббының) нигъмәтләренә шөкер итүче (иде)»** («ән-Нәхел», 121).

Локман галәйһис-сәләәм турында мондый юллар бар:

وَلَقَدْ آتَيْنَا لُقْمَانَ الْحِكْمَةَ أَنِ اشْكُرْ لِلَّهِ

**«Без Локманга хикмәтне “Аллаһка шөкер ит!” – дип бирдек»** («Локман», 12).

Төннәрен озын-озак намаз укып, Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең аяклары шешә. Хәзрәти Гайшә радыйаллаһу ганһә: «Йә, Рәсүлүллаһ! Син гафу-мәгъфирәткә лаек булган Хәбибуллаһ бит! Тәнеңне шулкадәр җәфалау килешерме?» – дигәч, Галәмнәр нуры: *«Әй, Гайшә! Шөкер итүче кол булмыйммыни?»* – дип белдерә (Бохари, «Тәфсир», 48/2; Мөслим, «Мүнафикин», 81).

Шөкер мәсьәләсе бик киң һәм тирән. Аны тулы дәрәҗәдә аңлату да мөмкин түгел. Чын шөкернең фазыйләтен һәм бәрәкәтен аны кичергән, тойган кешеләр генә төшенә ала. Кыскасы, һәркем үзенә бирелгән нигъмәткә нисбәтле рәвештә шөкер итәр өчен тырышырга бурычлы. Бу ни рәвешле башкарылырга тиеш?

Галимнәрнең шөкере Аллаһ аларга насыйп иткән гыйлемне бу белемнәрдән мәхрүм затларга өйрәтү һәм шул гыйлемнәр белән гамәл кылудан гыйбарәт. Имам Әгъзамның тормышы моның иң күркәм үрнәген тәшкил итә. Хәнәфи мәзһәбенә нигез салучы Имам Әгъзам Хәзрәтләре гомере буе гыйлемен Аллаһ юлында иң күркәм рәвештә тота, Иҗтиһад-хөкемнәре кыяматкә кадәр кулланылачак олуг мөҗтәһидләрдән Имам Әбү Йосыф, Имам Мөхәммәд, Имам Зөфәр кебек ислам дөньясын яктырткан бик күп галимнәрне тәрбияли. Гыйлемнең хөрмәтен һәм абруен саклап калып, аны залим хәлифә кулында ялган фәтвалар чыгару коралына әйләндермәс өчен, ул чорның иң дәрәҗәле урыннарыннан булган Багдад казые вазифасына караганда, төрмәләрдә череп, камчы белән кыйналуга өстенлек бирә.

Байларның шөкеренә килгәндә:

وَأَحْسِنْ كَمَا أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ

**«…Аллаһ сиңа игелек кылганы кебек, син дә игелек кыл!..»** аятендә («әл-Касас», 77) әйтелгәнчә эш йөртеп, мал-мөлкәтне Хак Тәгалә юлында кирәкле җирләргә сарыф итү күздә тотыла. Малның асыл хуҗасы Аллаһ икәнлеген аңлап, Ул биргән байлык белән горурланмау, мактанмау, исраф кылмау турында сүз бара. Кыскасы, «агния-и шакирин» (рәхмәтле, шөкер итүче байлар) булырга тырышу зарур.

Шөкер итүгә капма-каршы котыптагы исраф – Аллаһ биргән нигъмәткә кимсетеп карау, аны кадерсезләү, яман юлда куллану дигән сүз. Аяти кәримәдә бу мәсьәләдә куркыныч кисәтү ясала:

وَلَا تُبَذِّرْ تَبْذِيرًا إِنَّ الْمُبَذِّرِينَ كَانُوا إِخْوَانَ الشَّيَاطِينِ وَكَانَ الشَّيْطَانُ لِرَبِّهِ كَفُورًا

**«...Һәм, белештермичә, исраф итмә. Исраф итүче кешеләр – шайтаннарның кардәшләре. Шайтан исә – Раббысына карата инкярчы»** («әл-Исра», 26–27).

Иманлы-әхлаклы затлар шөкер кылуга ваемсыз хәлдә ашау-эчүне, киенүне һәм ниндидер әйберләр куллануны да исраф дип саный.

Күркәм әхлак иясенең шөкере үзендәге бөтен яхшы сыйфатларның Җәнабел-Хак рәхмәте һәм юмартлыгы нәтиҗәсе икәнен аңлау һәм, башка кешеләрне ким күрмичә, түбәнсетмичә, тәкъвалыгын саклап, бүтәннәргә үрнәк булудан гыйбарәт.

Сәйр вә сүлук әһле (суфилар) шөкере үзләре ияргән камил мөршидкә ихлас бәйләнеп, хәрәм белән хәләл мәсьәләсенә игътибар бирүдә, аяти кәримәдәге хәтта Хәзрәти Пәйгамбәрне дә картайткан:

فَاسْتَقِمْ كَمَا أُمِرْتَ وَمَنْ تَابَ مَعَكَ وَلَا تَطْغَوْا إِنَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ بَصِيرٌ

**«Син сиңа әмер ителгәнчә какшамас бул. Синең белән бергә тәүбә китерүчеләр дә (дөрес булсыннар)!..»** дигән әмердә кушылганча гамәл кылуда чагыла («Һуд», 112). Кыскасы, әдәп-әхлагыңны Коръән һәм сөннәткә нигезләү, Аллаһны танудан үзеңә өлеш алырга тырышу һәм мәхлукларга хезмәт итү дигән сүз. Рухи һәм әхлакый үрләрне яулагач, бу югарылыкларда нәфеснең рия, масаю кебек тозакларыннан саклану да булырга тиеш.

Сәламәт кешеләрнең һәм авыруларның шөкере, үз хәл-әхвәлләренең, Хак Тәгалә билгеләгән максатның бер шарты буларак, бу дөньяда вакытлы сынау өчен бирелгәнен аңлап, Аңа буйсыну һәм Аның сынауларына ризалык халәтендә яшәүне күздә тота. Сау-сәламәт кеше саулыгының аңа Аллаһ юлында изге эшләрдә файдалану өчен бирелгәнен белергә һәм шундый максатны гамәлгә ашыру омтылышы белән гомер итәргә тиеш. Авыру бәндә исә бу хәленең үзе өчен, бәлки, бик зур нигъмәт булу мөмкинлеге турында уйланырга бурычлы, «Йә, Раббы! Һәр хәлем өчен шөкерләр булсын!» дигән үзаң белән яшәү шарт. Шуны анык белү зарур: сукыр бер кеше, хәрәмнән һәм имеш-мимеш таратудан тыелганга күрә, күзләре күреп тә, хәрәм нәрсәләргә карау аркасында фетнәгә бирелүчедән никадәр отышлырак хәлдә гомер итә! Ләкин моның чын асылы кыямәт көнендә ачыкланачак.

Фәкыйрь кешеләрнең шөкере тормышны сабырлык белән бизәүдән гыйбарәт. Фукара-и сабирин (сабыр фәкыйрь) белән агния-и шакириннең Аллаһ ризалыгына ирешүдә мөмкинлекләре бертигез. Ярлы хәлдә шөкер итеп яшәү мәсьәләсендә Ибраһим ибне Әдһәм белән Шакыйк әл-Бәлхи әңгәмәсе бик гыйбрәтле.

Шакыйк әл-Бәлхи Ибраһим ибне Әдһәмнән: «Нишлисең? Хәл-әхвәлең ничек?» – дип сорый.

Ибраһим ибне Әдһәм: «Тапсам, шөкер итәм, таба алмасам, сабыр итәм!..» – дип җавап бирә. Шакыйк әл-Бәлхи: «Моны безнең Хорасан этләре дә шулай эшли!» – дигәч, Ибраһим ибне Әдһәмнән сорау килә: «Ярый, ә сез нишлисез

соң?» Шакыйк әл-Бәлхи җавабында болай ди: «Тапсак, шөкер итеп, инфак кылабыз, таба алмаган чагыбызда, сабыр итеп, шөкер кылабыз».

Барлык нигъмәтләр һәм әҗер-бүләкләр – Җәнабел-Хактан. Бу хакта Ибраһим Дәсуки куддисә сирруһ болай ди:

«И, туганым! Сак бул, үзеңә бирелгән берәр эшне һичшиксез башкара алачагың турындагы фикергә алданма! Соңыннан сәләтең аркасында үз-үзеңә ышаныч тойгысына бирелеп, хәлеңнән килмәгән эшкә алынырсың! Син шуны яхшы белергә тиеш: ураза тотасың икән, аны сиңа тоттыручы – Аллаһ Тәгалә. Намаз укыйсыңмы? Аллаһ каршында кыямда торасыңмы? Монысы да – Аның рәхмәте белән. Бөтен гамәлләр дә нәкъ әнә шулай. Һәрнәрсәнең Аннан икәнен беләчәксең...

Берәр нәрсә күргәндә, аны сиңа Аллаһ Тәгалә күрсәткәнен аңларга тиешсең. Бу халәтеңне саклап, рухи камиллек ширбәтеннән авыз иткәндә дә, янә: “Ул эчерде”, – дип әйтәчәксең».

Шәхси ихтыяр нәтиҗәсе булса да, һәр эш-гамәл Аллаһның «Халикъ» (Ялалтучы) сыйфатының бер чагылышы булганга күрә, һәрнәрсәнең Аннан килүен тану, белү – иман таләбе. Шуңа күрә «хәерленең дә, начарлыкның Аллаһтан» икәнлегенә ышану иманның бер шарты санала. Фәкать Аллаһның «ихтыяры» белән «ризалыгы»н бутарга ярамый, чөнки һәр эш Җәнабел-Хакның теләк-ихтыяры белән башкарыла, ә Аның ризалыгы исә бары хәерле нәрсәдә генә. Аллаһ ризалыгына туры килмәгән эш-гамәлнең кол теләге белән чынга ашуына Аның юл куюы мәсьәләсе исә бу дөньяның «сынау дөньясы» булуы белән аңлатыла.

Табибның максаты авыруны дәвалаудан гыйбарәт. Чирле кеше бирелгән даруны эчмәсә, дәваны алмаса, моңа табиб җавап тотмый. Шулай ук, әйтик, мөгаллимнең максаты – шәкертен тәрбияләп, уңышка ирештерү. Тик укучы тырышмаса, көч куймаса, мөгаллим берни дә эшли алмый. Аллаһ Тәгалә дә колын Дарус-Сәламгә (җәннәткә) чакыра. Әгәр кол бу чакыру шартларын үтәмәсә, нәтиҗәдә җәннәттән мәхрүм кала. Әгәр бәндәгә хәерледән яки яманнан берсен сайлау хокукы һәм мөмкинлеге бирелмәгән булса, ул очракта «җәза» һәм «әҗер-савап» төшенчәләре илаһи гаделлеккә каршы килер иде. Хәмед-сәнәләр әйтү һәм шөкер кылу – кол тарафыннан сайлап алынып, аның җәзага тартылуына яки әҗер-савап җыюына илтә торган иң мөһим гамәлләрдән берсе. Бәндә моны асыл мәгънәсендә төшенеп, шуларга ярашлы рәвештә гамәл кылып яшәргә бурычлы.

И, Раббыбыз! Безне Локман галәйһис-сәләәм шикелле, шөкер итеп хикмәттән үзенә насыйпны алучы, кулыннан, теленнән һәм күңеленнән өммәтең файда күрүче колларыңнан ит!

Амин!..



ХӘЗРӘТИ

# Зәкәрийя

*галәйһиссәләм*

*һәм*

ХӘЗРӘТИ

# Яхъя

*галәйһиссәләм*

*һәм*

ХӘЗРӘТИ

# Гайсә

*галәйһиссәләм*

***Пычкы белән икегә киселеп,***
***шәһид җибәрелгән мәзлум пәйгамбәр***

## ХӘЗРӘТИ ЗӘКӘРИЙЯ

***галәйһис-сәләәм;***

***Атасы кебек шәһид китеп, Раббысы белән кавышкан***

## ХӘЗРӘТИ ЯХЪЯ

***галәйһис-сәләәм ;***

***Авыруларга шифа биргән, үлеләрне терелткән,***
***күкләргә күтәрелгән***

## ХӘЗРӘТИ ГАЙСӘ

***галәйһис-сәләәм***

Бу өч пәйгамбәр, кичергән иза-җәфалары һәм тәүхид дин өчен куйган тырышлыклары ягыннан, бер-берсенә бик охшаш. Муса галәйһис-сәләәмнән соң коточкыч бозыклыкка чумган азгын яһүдиләрне кабат һидәят юлына кертү өчен, алар бик зур көч салган. Ләкин аларга ияргән бер төркемнән кала, иманга килмәгән зур күпчелек тарафыннан даими рәвештә төрлечә мыскыл ителгәннәр, кимсетелгәннәр, җәзаланганнар, дөньялыктагы тормышларын алар мең дә бер газап һәм иза-җәфалар эчендә уздыра. Хәтта Зәкәрийя һәм Яхъя галәйһимәс-сәләмгә шәһидлек ширбәтен эчәргә насыйп була, Гайсә галәйһис-сәләәм исә Җәнабел-Хак тарафыннан күккә күтәрелә.

Әлеге өч пәйгамбәрнең, рәсүллек вазифаларын башкаргандагы сынаулар охшашлыгы белән беррәттән, араларында туганлык элемтәсе дә, бер-берсенә рухи тәрбия бирүдә чагылган бәйләнешләр дә бар.



**Зәкәрийя галәйһис-сәләәм**

Зәкәрийя галәйһис-сәләәм – нәсел-нәсәбе Сөләйман галәйһис-сәләәмгә тоташкан Бәни Исраил пәйгамбәре. Иерусалимдәге «әл-Әкъса» мәчетендә Тәүрат язу белән шөгыльләнә һәм корбан чалу эше белән җитәкчелек итә, шул рәвешле Муса галәйһис-сәләәм динен ныгыта. Зәкәрийя галәйһис-сәләәм балта остасы була, кул көче белән хезмәт куеп яши. Кавеме тарафыннан шәһид җибәрелә, төрбәсе – Алеппо шәһәрендә.

Зәкәрийя галәйһис-сәләәм чорында Димәшкъ һәм Иерусалим птолемейчылар кулында була. Алар, Иерусалимне хөрмәт итеп, Исраил угылларына карата яхшы мөнәсәбәт саклый. Птолемейчылар кавеменең абруйлы затлары гыйбадәтханәдән бөтенләй чыкмыйча, Бәйтүл-Макдистә көн-төн гыйбадәт кыла. Ул заманнарда Исраил угыллары арасында бер пәйгамбәр дә булмый. Үзләренә берәр пәйгамбәр җибәрсен өчен, алар Аллаһка ялвара. Шуннан соң Зәкәрийя галәйһис-сәләәм Аллаһ Җәллә Җәләлүһү тарафыннан пәйгамбәр итеп җибәрелә.

Иерусалимдә дүрт йөз ирекле изге зат даими гыйбадәт кыла. Берәр кеше, Аллаһ каршында хөрмәт казанырга теләсә, хатыны авырга узгач: «Йә, Раббы! Улым туса, гыйбадәт кылу өчен, аны Бәйтүл-Макдискә нәзер итеп бирер идем», – дип әйтә торган була.

Шулай итеп ир балалар мәҗбүри рәвештә Бәйтүл-Макдискә нәзер итеп тапшырыла. Бу гадәт Муса галәйһис-сәләәм заманыннан ук калган була. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Муса галәйһис-сәләәмгә болай дип боера: «И, Муса! Мин колларымнан шундый кешене яратам: кем яшь чагыннан башлап, картаймыш көненә кадәр гомерен гыйбадәттән үткәрә, кем яшь вакытында гөнаһ кылмый һәм, күңелен Миңа гына биреп, Минем сөюемне казана».

Зәкәрийя галәйһис-сәләәм Сөләйман галәйһис-сәләәмнең нәселеннән булган Әлиса белән өйләнешә. Әлиса Мәрьямнең әнисе Ханнәнең апасы була. Ханнәнең ире – Гыймран. Зәкәрийя галәйһис-сәләәм белән Әлиса гаиләсендә Яхъя галәйһис-сәләәм дөньяга килә.

Зәкәрийя галәйһис-сәләәм изге һәм тугры пәйгамбәр буларак гомер кичерә, югарыда әйтеп үтелгәнчә, явыз һәм азгын яһүдиләр тарафыннан ерткычларча үтерелә.

**Яхъя галәйһис-сәләәм**

Яхъя галәйһис-сәләәм Хәзрәти Мәрьям белән туганнан туганнар була. Ул кече яшьтән үк Тәүратны өйрәнә, балигълык чорына җиткәч, аңа пәйгамбәрлек вазифасы йөкләнә.

Зәкәрийя галәйһис-сәләәмгә Хәзрәти Яхъя бүләк ителүе турында Коръәни-Кәримдә болай дип телгә алына:

هُنَالِكَ دَعَا زَكَرِيَّا رَبَّهُ قَالَ رَبِّ هَبْ لِي مِنْ لَدُنْكَ ذُرِّيَّةً طَيِّبَةً إِنَّكَ سَمِيعُ الدُّعَاءِ

**«Зәкәрийя анда (Иерусалимдә) Раббысына дога кылган иде һәм: “И, Раббым! Миңа да Үзеңнән пакь бер нәсел насыйп ит. Һичшиксез, син – доганы Ишетүче”, – дип әйткән иде»** («Әли Гыймран», 38).

قَالَ رَبِّ إِنِّي وَهَنَ الْعَظْمُ مِنِّي وَاشْتَعَلَ الرَّأْسُ شَيْبًا وَلَمْ أَكُنْ بِدُعَائِكَ رَبِّ شَقِيًّا

**«Ул әйтте: “И, Раббым! (Мин шул хәлгә җиттем ки), сөякләрем бушады, башымны да чал каплады. Әмма, И, Раббым, мин Сиңа дога белән һич мәхрүм ителгән булмадым!”»** («Мәрьям», 4).

وَإِنِّي خِفْتُ الْمَوَالِيَ مِنْ وَرَائِي وَكَانَتِ امْرَأَتِي عَاقِرًا فَهَبْ لِي مِنْ لَدُنْكَ وَلِيًّا

**«Һичшиксез, мин артымнан идарә эшенә үтүчеләрдән куркамын. Хатыным исә кысыр булды. Син миңа Үз хозурыңнан мирасчы (угыл) бир!»** («Мәрьям», 5).

يَرِثُنِي وَيَرِثُ مِنْ آلِ يَعْقُوبَ وَاجْعَلْهُ رَبِّ رَضِيًّا

**«Ул миңа да варис булсын, Ягъкуб гаиләсеннән бер өлешенә дә мирасчы булсын. И, Раббым! Син аны Үзең разый булган бер кемсә ит!»** («Мәрьям», 6).

Зәкәрийя галәйһис-сәләәмнең ихлас күңелдән кылган бу самими догасы Аллаһ катында кабул була:

فَنَادَتْهُ الْمَلَائِكَةُ وَهُوَ قَائِمٌ يُصَلِّي فِي الْمِحْرَابِ أَنَّ اللَّهَ يُبَشِّرُكَ بِيَحْيَىٰ
مُصَدِّقًا بِكَلِمَةٍ مِنَ اللَّهِ وَسَيِّدًا وَحَصُورًا وَنَبِيًّا مِنَ الصَّالِحِينَ

**«Ул (Зәкәрийя) михрабта аягүрә намаз укыган чакта, фәрештәләр аңа: “Аллаһ сине, Аллаһтан бер сүзне исбатлаучы буларак, сәед, тотнаклы һәм изгеләрдән бер пәйгамбәр булачак Яхъя белән сөендерә”, – дип мөрәҗәгать кылды»** («Әли Гыймран», 39).

Мөфәссирләр аңлатканча, аятьтәге **«кәлимә»** сүзе белән Хәзрәти Гайсә телгә алына. «Әли Гыймран» сүрәсенең 45 нче аяти кәримәсе дә моны ап-ачык хәбәр итә. Икенче бер аяти кәримәдә болай диелә:

يَا زَكَرِيَّا إِنَّا نُبَشِّرُكَ بِغُلَامٍ اسْمُهُ يَحْيَىٰ لَمْ نَجْعَلْ لَهُ مِنْ قَبْلُ سَمِيًّا

**«(Аллаһ әйтте:) “И, Зәкәрийя! Һичшиксез, Без сине бер ир бала белән сөендерәбез, аның исеме – Яхъя. Моңарчы Без аңа адаш итмәгән идек!”»** («Мәрьям», 7).

Аятьтә **«Моңарчы Без аңа адаш итмәгән идек!»** дигән сүзләр Хәзрәти Яхъяга хөрмәтне белдерә. Чөнки Яхъя исеме беренче тапкыр Аңа кушыла, өстәвенә шәхсән Җәнабел-Хак тарафыннан җибәрелә. Шул ук вакытта бу Яхъя галәйһис-сәләәм ия булган башка искиткеч фазыйләтләрне дә белдерә.

«Яхъя» – яшәүче, тере дигән мәгънәдәге исем. Ике карт кешегә бала бүләк ителү үледән тере кеше яралтуга тиң. Аяти кәримәләрдә бу вакыйга түбәндәгечә искә алына:

قَالَ رَبِّ أَنَّىٰ يَكُونُ لِي غُلَامٌ وَقَدْ بَلَغَنِيَ الْكِبَرُ وَامْرَأَتِي عَاقِرٌ قَالَ كَذَٰلِكَ اللَّهُ يَفْعَلُ مَا يَشَاءُ

**«Ул (Зәкәрийя:): "И, Раббым! Миңа инде картлык килгәч, хатыным исә кысыр була торып, ничек минем улым була алсын?" – дигән иде. Ул (Аллаһ): "Аллаһ теләгәнен шулай эшли", – дигән иде»** («Әли Гыймран», 40).

قَالَ كَذَٰلِكَ قَالَ رَبُّكَ هُوَ عَلَيَّ هَيِّنٌ وَقَدْ خَلَقْتُكَ مِنْ قَبْلُ وَلَمْ تَكُ شَيْئًا

**«(Аллаһ:) әйтте: "Шулай була! Раббың: "Бу Миңа бик җиңел. Моңа кадәр, син булмаганда, Мин сине бар иткән идем бит", – диде»** («Мәрьям», 9).

Догасы кабул ителүнең билгеләре сыйфатында Зәкәрийя галәйһис-сәләәм кешеләр белән өч көн буе ым-ишарә белән генә сөйләшә ала, аңа Раббысын зикер кылу мөмкинлеге генә бирелә:

قَالَ رَبِّ اجْعَلْ لِي آيَةً قَالَ آيَتُكَ أَلَّا تُكَلِّمَ النَّاسَ ثَلَاثَةَ أَيَّامٍ
إِلَّا رَمْزًا وَاذْكُرْ رَبَّكَ كَثِيرًا وَسَبِّحْ بِالْعَشِيِّ وَالْإِبْكَارِ

**«Ул (Зәкәрийя:): "И, Раббым! Миңа (улым булачагы турында) бер билге күрсәт!" – дигән иде. Ул (Аллаһ): "Синең билгең: өч көн кешеләр белән сөйләшә алмассың, фәкать ишарәләр аша гына (аралашырсың). Ләкин Раббыңны күп итеп зикер ит, кичкә каршы һәм таңга каршы исә тәсбихтә бул", – дигән иде»** («Әли Гыймран», 41).

Зәкәрийя галәйһис-сәләәм өч көн дәвамында кешеләр белән бөтенләй сөйләшә алмый. Кавемен дингә өндәү эшен туфракка язу һәм ишарәтләр ярдәмендә башкара:

فَخَرَجَ عَلَىٰ قَوْمِهِ مِنَ الْمِحْرَابِ فَأَوْحَىٰ إِلَيْهِمْ أَنْ سَبِّحُوا بُكْرَةً وَعَشِيًّا

**«Ул (Зәкәрийя) михрабтан кавеменә чыкты да: "Иртә-кич тәсбих итегез!" – дип аларга аңлатты»** («Мәрьям», 11).

Җәнабел-Хак әйтә:

فَاسْتَجَبْنَا لَهُ وَوَهَبْنَا لَهُ يَحْيَىٰ وَأَصْلَحْنَا لَهُ زَوْجَهُ إِنَّهُمْ كَانُوا يُسَارِعُونَ فِي الْخَيْرَاتِ وَيَدْعُونَنَا رَغَبًا وَرَهَبًا وَكَانُوا لَنَا خَاشِعِينَ

**«Без аңа җавап бирдек һәм аңа Яхъяны бирдек, хатынын да аның өчен төзәттек (бала табу сәләте насыйп иттек). Һичшиксез, алар (барлык пәйгамбәрләр) хәерле эшләргә омтылалар һәм көчле бер теләк вә курку белән Безгә ялваралар иде. Алар Безгә карата тыйнак кешеләр иде»** («әл-Әнбия», 90).

Яхъя галәйһис-сәләәм үсеп җиткәч, Аллаһ Тәгалә аңа Тәүратка ябышыр-га, аның кануннарын үтәргә боера:

يَا يَحْيَىٰ خُذِ الْكِتَابَ بِقُوَّةٍ وَآتَيْنَاهُ الْحُكْمَ صَبِيًّا

**«“И, Яхъя! Китапны (Тәүратны) нык ал!” Без аңа бала чагында ук (гыйлем һәм) хөкем биргән идек!»** («Мәрьям», 12).

وَحَنَانًا مِنْ لَدُنَّا وَزَكَاةً وَكَانَ تَقِيًّا

**«Һәм Үзебездән генә шәфкать һәм бәрәкәт (бирдек). Ул тәкъвалык иясе иде»** («Мәрьям», 13).

وَبَرًّا بِوَالِدَيْهِ وَلَمْ يَكُنْ جَبَّارًا عَصِيًّا

**«Ата-анасына карата бик итагатьле иде. Ул тәкәббер һәм тискәре булмады»** («Мәрьям», 14).

Хәзрәти Яхъяга пәйгамбәрлек вазифасы йөкләнә. Ләкин Гайсә галәй-һис-сәләәмгә пәйгамбәрлек һәм Инҗил җибәрелгәнче, ул Муса галәй-һис-сәләәм шәригатенә буйсына. Муса галәйһис-сәләәм шәригате белән гамәл кылган иң соңгы пәйгамбәр булып тора. Яхъя галәйһис-сәләәм дә атасы Зәкәрийя галәйһис-сәләәм кебек шәһид китә.

Муса галәйһис-сәләәм шәригатенә күрә, бертуганыңның хатынына өйләнү тыела. Моның җәзасы исә кысырлыктан гыйбарәт була (Левиләр, 18/6–18; 20/19–21). Тәүратта читләр белән зина кылуга үлем җәзасы каралган булса, өйләнешү тыелган кешеләр арасындагы зина өчен җәза аерыла (Канун, 22/22–27; Левиләр, 20/11, 12, 14, 17). Хәзрәти Яхъяның шәһид китүенә дә сәбәп булган бу мәсьәлә белән бәйле бер вакыйга риваять кылына:

Хәзрәти Яхъя пәйгамбәр вакытта Король Һерот I (Һиродес, Ирод) бер-туганының хатыны белән зина кыла. Моның илаһи кануннарга каршы килүе турында әйткәч, король Хәзрәти Яхъяны төрмәгә яптыра. Аннары бу король зина кылган хатынның кызы белән корольнең туган көне бәйрәменә килә.

Ул кыз үз-үзен тотышы, кыланмышлары белән корольне, әйтерсең, сихерләп ала, тәмам һушсыз калдыра. Король ул көнне кыз ни теләсә, шуны үтәргә сүз бирә. Әнисе тарафыннан котыртып торылган кыз Хәзрәти Яхъяның башын сорый. Бу теләкне ишеткән король бик кайгыра, ләкин сүз биргәнен онытмый һәм шулай итеп Хәзрәти Яхъя, башы чабылып, шәһид җибәрелә (Лука Инҗиле, 3/19–20; Матфей (Маттай) Инҗиле, 14/1–12).

Бер риваятькә күрә, Яхъя галәйһис-сәләәм, башы әллә ничә кат киселгәннән соң да, явыз Һеротка: «Сиңа бу кыз белән булырга ярамый!..» – дип мөрәҗәгать итә. Ваемсызлыгы шулкадәр була ки, Яхъя галәйһис-сәләәмнең пәйгамбәрлек могҗизаларын күргән килеш тә, кабахәт Һерот I аңа каршы килә һәм үтертә. Яхъя галәйһис-сәләәмнең мөбарәк җәсәде төрле шәһәрләргә тарала. Башы Димәшкътәге Өмәййә мәчетендә җирләнгән. Һерот өйләнгән кызны исә соңыннан җир йота.

Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәмнең күккә күтәрелүе дә шушы вакытларга туры килә, чөнки ул чорда яһүдиләр пәйгамбәрләрне үтерерлек дәрәҗәдә бозылган, явызланган була. Әлеге гамәлләре һәм шуңа охшаш бик күп җинаятьләре, азгынлыклары сәбәпле, Җәнабел-Хак аларны ләгънәт кыла:

فَبِمَا نَقْضِهِمْ مِيثَاقَهُمْ وَكُفْرِهِمْ بِاٰيَاتِ اللّٰهِ وَقَتْلِهِمُ الْاَنْبِيَٓاءَ بِغَيْرِ حَقٍّ
وَقَوْلِهِمْ قُلُوبُنَا غُلْفٌ بَلْ طَبَعَ اللّٰهُ عَلَيْهَا بِكُفْرِهِمْ فَلَا يُؤْمِنُونَ اِلَّا قَلِيلًا

**«Вәгъдәләрен бозганнары, Аллаһның аятьләрен инкяр иткәннәре, нахакка пәйгамбәрләрне үтергәннәре һәм: “Безнең күңелләребез пәрдәләнгән”, – дигәннәре өчен (аларга ләгънәт кылдык, башларына төрле бәлаләр җибәрдек. Аларның йөрәкләре пәрдәләнмәгән). Дөреслектә, Аллаһ, көферлекләре сәбәпле, аларга мөһер сукты. Бик азларыннан тыш, алар иман китермиләр»** («ән-Ниса», 155).

Шәһидлек үлемен татыган чакта, Яхъя галәйһис-сәләәм утыз яшен узган була.

Аяти кәримәдә дә хәбәр ителгәнчә, ул өч куркыныч көндә Аллаһ Тәгаләнең рәхмәтенә лаек була:

وَسَلَامٌ عَلَيْهِ يَوْمَ وُلِدَ وَيَوْمَ يَمُوتُ وَيَوْمَ يُبْعَثُ حَيًّا

**«Сәлам булсын аңа, туган көнендә дә, үләсе көнендә дә, тере булып чыгарылачак көнне дә!»** («Мәрьям», 15).

Бәйзави бу аятькә мондый аңлатма бирә: «Кешеләрне бимазалап торучы шайтан аңа тормышында зарар бирмәсен! Кабер газабыннан имин булсын! Хисап көне куркуын һәм җәһәннәм газабын күрмәсен!»

**Гайсә галәйһис-сәләәм**

Гайсә галәйһис-сәләәм, Яхъя галәйһис-сәләәм туганнан соң алты ай узгач, Иерусалимдә дөньяга килә. Гайсә галәйһис-сәләәм Исраил угылларына җибәрелгән иң соңгы пәйгамбәр була.

Пәйгамбәрләр арасында иң хөрмәтле, иң бөек, «үлүл-газыйм» дип аталган биш пәйгамбәрнең дүртенчесе ул. Аның «Рухуллаһ» дип йөртелүе, үзенә күрә хөрмәтләү билгесе булу белән бергә, Аллаһ Тәгаләнең, Хәзрәти Адәмне яралткан кебек, аны да Үз рухыннан өреп яралтуы белән бәйле.

Гайсә галәйһис-сәләәмгә утыз яшендә пәйгамбәрлек вазифасы бирелә, изге китап буларак, аңа Инҗил иңдерелә. Гайсә галәйһис-сәләәм утыз өч яшендә тере килеш күккә аша.

Кыямәт якынайгач, ул кабат дөньяга төшәчәк, өйләнеп, балалары туачак, «Хәзрәти Мәһди» белән очрашачак, исламны бар җиһанга хаким дингә әйләндерәчәк һәм Мәдинәи Мөнәввәрәдә вафат булачак. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез җирләнгән Сәгадәт бүлмәсендәге хөрмәтле төрбә янына дәфен кылыначак.

Гайсә галәйһис-сәләәмнең әнисе Хәзрәти Мәрьям Давыт галәйһис-сәләәм нәселеннән килә. Аның анасы – Ханнә, атасы – Гыймран. Чыганакларда әйтелгәнчә, Ханнәнең баласы булмый һәм ул: «Йә, Раббы! Минем берәр балам булса, аны Бәйтүл-Макдискә хезмәтче итәр идем!» – дип нәзер әйтә. Шушы нәзердән соң Ханнә авырга уза. Аяти кәримәдә болай дип хәбәр ителә:

إِذْ قَالَتِ امْرَأَتُ عِمْرَانَ رَبِّ إِنِّي نَذَرْتُ لَكَ مَا فِي بَطْنِي مُحَرَّرًا فَتَقَبَّلْ مِنِّي إِنَّكَ أَنْتَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ

**«Менә Гыймранның хатыны: “И, Раббым! Мин карынымдагыны азат ителгән (кол) буларак, Синең өчен нәзер иттем. Миннән (нәземне) кабул әйлә. Һичшиксез, Син – (үтенечемне) Ишетүче, (ниятемне) Белүче!” – дигән иде»** («Әли Гыймран», 35).

Күпмедер вакыттан соң, Ханнә кыз бала таба. Аңа Мәрьям дип исем куша:

فَلَمَّا وَضَعَتْهَا قَالَتْ رَبِّ إِنِّي وَضَعْتُهَا أُنْثَىٰ وَاللَّهُ أَعْلَمُ بِمَا وَضَعَتْ وَلَيْسَ الذَّكَرُ
كَالْأُنْثَىٰ وَإِنِّي سَمَّيْتُهَا مَرْيَمَ وَإِنِّي أُعِيذُهَا بِكَ وَذُرِّيَّتَهَا مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ

**«Ләкин аны тудыргач, Аллаһ исә аның кемне тудырганын яхшырак белсә дә, ул: “И, Раббым! Мин кыз бала тудырдым. Кыз бала ир бала кебек түгел бит. Мин аңа Мәрьям исеме куштым. Һичшиксез, мин аны да, аның токымын да ташлар атылган шайтаннан Сиңа сыендырамын!” – дигән иде»** («Әли Гыймран», 36).

Ул вакытка кадәр Бәйтүл-Макдискә ир балаларны нәзер итеп бирү рөхсәт ителә һәм бик саваплы санала. Шул рәвешле нәзер ителгән малайлар туган көненнән балигъльк вакытына хәтле бары шунда гына хезмәт итә. Балигъльк яшенә җиткәч, теләсә, шунда ук хезмәтен дәвам итә, теләсә, үзенә ошаган башка берәр җиргә китә. Тик балигъльк вакытына кадәр Бәйтүл-Макдистән китәргә рөхсәт ителми.

Мондый нәзерне ир балалар өчен генә әйтәләр. Мәрьям турында үтенечне кабул итеп, Аллаһ Тәгалә кыз балаларның да нәзер итеп әйтелүенә ризалыгын белдерә, шуннан соң кыз балаларның да Бәйтүл-Макдискә нәзер итеп бирелүе тыелмый башлый.

Ханнә кызы Мәрьямне Бәйтүл-Макдистәге хезмәткәрләр кулына тапшыра. Мәрьямне кем үз химаясенә алачагы мәсьәләсендә шобага салалар. Аллаһ Тәгалә әйтә:

ذَٰلِكَ مِنْ أَنْبَاءِ الْغَيْبِ نُوحِيهِ إِلَيْكَ وَمَا كُنْتَ لَدَيْهِمْ إِذْ يُلْقُونَ
أَقْلَامَهُمْ أَيُّهُمْ يَكْفُلُ مَرْيَمَ وَمَا كُنْتَ لَدَيْهِمْ إِذْ يَخْتَصِمُونَ

**«(Рәсүлем!) Бу – Без сиңа вәхи иткән гаиб хәбәрләрдән. Аларның кайсысы Мәрьямне тәрбиягә алыр, дип, каләмнәрен ташлаган (шобага салган) чакларында Син алар янында түгел идең. Алар (шул сәбәпле) тартышкан вакытта да, Син яннарында түгел идең»** («Әли Гыймран», 44).

Шобага Бәйтүл-Макдис имамы, Ханнәгә кияү тиешле Зәкәрийя галәйһис-сәләәмгә чыга. Зәкәрийя галәйһис-сәләәм: «Аның түтәсе минем никахым (хатыным) астында», – ди һәм Мәрьямне үз тәрбиясенә ала. Мәрьям күкрәктән аерылгач, аңа Бәйтүл-Макдистә бер бүлмә бүлеп бирелә. Әлеге бүлмә аяти кәримәдә «михраб» дип искә алына. Михраб – «табыну, гыйбадәт урыны» дигән сүз.

Хәзрәти Мәрьямнең бүлмәсенә Зәкәрийя галәйһис-сәләәм генә кереп йөри. Бу хәл Мәрьямгә унике яшь тулганчы дәвам итә. Зәкәрийя галәйһис-сәләәм, аның бүлмәсенә ачкычы белән ишекне ачып керә, чыкканда, бикләп чыга. Кызга бер көнгә җитәрлек ризык калдыра. Ләкин бүлмә эчендә төрле җиләк-җимеш күреп гаҗәпләнә. Аларны каян килгәнен сорагач, Мәрьям бу нигъмәтләрнең Аллаһ тарафыннан җибәрелгәнен әйтә. Әлеге ризыклар арасында җәен – кышкы, кышын җәйге җиләк-җимешләр була. Аллаһ Тәгалә әйтә:

فَتَقَبَّلَهَا رَبُّهَا بِقَبُولٍ حَسَنٍ وَأَنْبَتَهَا نَبَاتًا حَسَنًا وَكَفَّلَهَا زَكَرِيَّا
كُلَّمَا دَخَلَ عَلَيْهَا زَكَرِيَّا الْمِحْرَابَ وَجَدَ عِنْدَهَا رِزْقًا قَالَ يَا مَرْيَمُ أَنَّىٰ لَكِ
هَٰذَا قَالَتْ هُوَ مِنْ عِنْدِ اللَّهِ إِنَّ اللَّهَ يَرْزُقُ مَنْ يَشَاءُ بِغَيْرِ حِسَابٍ

**«Раббысы аны (Мәрьямне) яхшы бер ризалык белән кабул итте һәм аны яхшы тәрбия белән үстерде, аны Зәкәрийягә тапшырды. Зәкәрийя кайчан гына аның янына михрабка кермәсен, аның янында ризык таба иде һәм: “И, Мәрьям! Бу сиңа каян (килә)?” – дип әйтә, ул исә: “Бу – Аллаһ хозурыннан. Һичшиксез, Аллаһ Үзе теләгәнен хисапсыз ризыкландыра”, – дия иде»** («Әли Гыймран», 37).

Аллаһ Җәллә Җәләлүһүнең Хәзрәти Мәрьямгә насыйп иткән иң зур нигъмәт-мөмкинлекләре мондый:

1) Ул вакытка кадәр Бәйтүл-Макдискә ир балаларны гына нәзер итеп биргән булсалар, әнисе Ханнәнең үтенече белән Мәрьям дә нәзер бала сыйфатында кабул ителә.

2) Аллаһ Тәгалә Мәрьямне Зәкәрийя галәйһис-сәләәм тәрбиясенә бирә.

3) Җәннәт нигъмәтләреннән булган ризык насыйп кыла.

4) Пәйгамбәрләренә җибәрә торган фәрештә – Җәбраил галәйһис-сәләәм белән очраштыра.

5) Аны һәм улы Хәзрәти Гайсәне шайтан явызлыгыннан саклый.

6) Улы Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәм карында вакытта ук сөйләшә. Әнисенә ягылган ялаларга җавап бирә.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез:

*«Гыймран кызы Мәрьям үз заманында дөньядагы хатын-кызларның иң хәерлесе була. Бу өммәтнең хатыннарыннан иң хәерлесе исә – Хатиҗә»*, – дип әйткән (Мөслим, «Фәдаилүс-Сахабә», 69).

Хәзрәти Мәрьям көн-төн гыйбадәт кыла. Аның тәкъвалыгы Бәни Исраил халкы арасында бер хөрмәтле легендага әйләнә. Аның белән бәйле кәрамәт-могҗизалар барлыкка килә. Хәзрәти Мәрьям – Аллаһның сайлап алынган колларыннан. Коръәни-Кәримдә ул «сыйддика» дип хөрмәт белән телгә алына.

Аллаһ Тәгалә болай ди:

وَإِذْ قَالَتِ الْمَلَائِكَةُ يَا مَرْيَمُ إِنَّ اللَّهَ اصْطَفَاكِ وَطَهَّرَكِ وَاصْطَفَاكِ عَلَىٰ نِسَاءِ الْعَالَمِينَ

**«Фәрештәләр әйткән: “И, Мәрьям! Һичшиксез, Аллаһ сине сайлап алды, сине пакь кылды һәм галәмнәрнең хатын-кызларыннан өстен кылды”»** («Әли Гыймран», 42).

يَا مَرْيَمُ اقْنُتِي لِرَبِّكِ وَاسْجُدِي وَارْكَعِي مَعَ الرَّاكِعِينَ

**«И, Мәрьям! Раббыңа итагатьле бул, сәҗдә кыл һәм (Аның хозурында) рөкүгъ кылганнар белән бергә рөкүгъ кыл!»** («Әли Гыймран», 43).

Шушы илаһи әмерләрдән соң Хәзрәти Мәрьямнең тәкъвалыгы шул дәрәҗәгә җитә ки, аяклары тәмам шешенгәнче намаз кыла торган була.

**Юктан бар итүче атасыз да яралтыр!**

Хәзрәти Мәрьямгә унбиш яшь чагында, аны Йосыф әл-Нәҗҗар исемле бер ир-ат белән ярәшеп куялар. Ләкин Аллаһ Тәгалә Мәрьямгә сөенечле хәбәр җибәрә: бу ир-атка кияүгә чыкканчы, атасыз бала бирәчәген белдерә. Аяти кәримәдә әйтелә:

إِذْ قَالَتِ الْمَلَائِكَةُ يَا مَرْيَمُ إِنَّ اللَّهَ يُبَشِّرُكِ بِكَلِمَةٍ مِنْهُ اسْمُهُ الْمَسِيحُ
عِيسَى ابْنُ مَرْيَمَ وَجِيهًا فِي الدُّنْيَا وَالْآخِرَةِ وَمِنَ الْمُقَرَّبِينَ

**«Фәрештәләр әйттеләр: “И, Мәрьям! Һичшиксез, Аллаһ сине Үзеннән бер сүзе белән сөендерә ки, аның исеме – Мәсих,[167] Мәрьям улы Гайсә. Ул дөньяда да, Ахирәттә дә кадер-хөрмәт иясе һәм якын кылынганнардан булачак”»** («Әли Гыймран», 45).

Фәрештәләр Хәзрәти Мәрьямгә өстәп болай диләр:

وَيُكَلِّمُ النَّاسَ فِي الْمَهْدِ وَكَهْلًا وَمِنَ الصَّالِحِينَ

**«(И, Мәрьям!) Ул бишектә дә, үсеп җиткәч тә кешеләргә сөйләячәк һәм изгеләрдән булачак»** («Әли Гыймран», 46).

Шуннан соң:

قَالَتْ رَبِّ أَنَّىٰ يَكُونُ لِي وَلَدٌ وَلَمْ يَمْسَسْنِي بَشَرٌ قَالَ كَذَٰلِكِ اللَّهُ
يَخْلُقُ مَا يَشَاءُ إِذَا قَضَىٰ أَمْرًا فَإِنَّمَا يَقُولُ لَهُ كُنْ فَيَكُونُ

**«Ул (Мәрьям): “И, Раббым! Миңа бер (ир-ат) кеше дә кагылмагач, ничек итеп минем балам була алсын?” – дигән иде. Ул (Аллаһ): “(Әнә шулай). Аллаһ Үзе теләгәнен шулай бар итә. Ул карар биргәч, аңа: “Бул!” – дип кенә әйтер, һәм ул бар булыр”, дигән иде»** («Әли Гыймран», 47).

Фәрештәләр Хәзрәти Гайсә турында Мәрьямгә аталган сүзләрен дәвам итә:

وَيُعَلِّمُهُ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَالتَّوْرَاةَ وَالْإِنْجِيلَ

**«Ул (Аллаһ) китапларны, хикмәтне, Тәүратны һәм Инҗилне өйрәтәчәк!»** («Әли Гыймран», 48).

---

167. Мәсих – иврит сүзе, Хәзрәти Гайсәнең кушаматы, «изге, мөбарәк» дигән мәгънә белдерә.

Югарыдагы аяти кәримәләрдә гомуми буларак телгә алынган **«фәрештәләр»** сүзе белән Җәбраил галәйһис-сәләәм күз уңында тотыла. Әлеге фәрештәне зурлау, хөрмәтләү өчен, аның турында шул рәвешле күплек санда искә алына.

Җәнабел-Хак болай ди:

وَاذْكُرْ فِي الْكِتَابِ مَرْيَمَ إِذِ انْتَبَذَتْ مِنْ أَهْلِهَا مَكَانًا شَرْقِيًّا

**«(Рәсүлем!) Китапта Мәрьямне дә искә ал. Менә ул, гаиләсеннән аерылып, көнчыгыштагы бер җиргә китте»** («Мәрьям», 16).

Әлеге аятьтәге **«көнчыгыш тарафы»**, мөфәссирләр фикеренчә, «әл-Әкъса» мәчетенең көнчыгыш ягы яки Мәрьямнең өенең көнчыгыш ягы дип аңлатыла. Христианнар әнә шуңа күрә көнчыгышка карап гыйбадәт кыла дип санала.

Озак та үтми, Аллаһ Тәгалә Хәзрәти Мәрьям янына Җәбраил галәйһис-сәләәмне җибәрә. Аяти кәримәдә:

فَاتَّخَذَتْ مِنْ دُونِهِمْ حِجَابًا فَأَرْسَلْنَا إِلَيْهَا رُوحَنَا فَتَمَثَّلَ لَهَا بَشَرًا سَوِيًّا

**«(Мәрьям) пәрдә корып, алардан ышыкланды. Шулчак Без Рухыбызны аңа җибәрдек, һәм ул аңа бер кеше буларак күренде»**, – дип әйтелә («Мәрьям», 17).

Мондагы Рух сүзе белән Җәбраил галәйһис-сәләәм белдерелә. Һәр әгъзасы исән-сау булган яшь кеше кыяфәтендә җибәрелүенең сәбәбе исә Мәрьямне куркытмау, өркетергә теләмәү белән бәйле, чөнки Хәзрәти Мәрьям Җәбраил галәйһис-сәләәмне чын, асыл кыяфәтендә күрсә, һичшиксез, күңеленә курку-шом керми калмас иде.

Ләкин Хәзрәти Мәрьям, каршында яшь ир-егет күргәч, камил әдәплелеге һәм гыйффәтлелеге сәбәпле, барыбер бик куркуга төшә. Бу ир-егетнең Хәзрәти Җәбраил икәнлеген белмәгәнгә күрә, бик нык борчыла, дулкынлана башлый һәм аяти кәримәләрдә әйтелгәнчә:

قَالَتْ إِنِّي أَعُوذُ بِالرَّحْمٰنِ مِنْكَ إِنْ كُنْتَ تَقِيًّا

**«Ул (Мәрьям): “Мин синнән (бик саклаучы булган) Рахманга сыенамын. Әгәр син тәкъвалык иясе булсаң, (миңа кагылма)!” – диде»** («Мәрьям», 18).

قَالَ إِنَّمَا أَنَا رَسُولُ رَبِّكِ لِأَهَبَ لَكِ غُلَامًا زَكِيًّا

**«Ул (фәрештә): “Мин сиңа саф бер ир бала бирер өчен Раббыңның илчесе генәмен”, – диде»** («Мәрьям», 19).

قَالَتْ أَنَّىٰ يَكُونُ لِي غُلَامٌ وَلَمْ يَمْسَسْنِي بَشَرٌ وَلَمْ أَكُ بَغِيًّا

**«(Мәрьям:) Ул: “Ничек минем ир балам була алсын? Миңа бит бер кеше дә кагылмады, мин зина кылучы булмадым”, – диде»** («Мәрьям», 20).

قَالَ كَذَٰلِكِ قَالَ رَبُّكِ هُوَ عَلَيَّ هَيِّنٌ وَلِنَجْعَلَهُ آيَةً لِلنَّاسِ وَرَحْمَةً مِنَّا وَكَانَ أَمْرًا مَقْضِيًّا

**«Ул (фәрештә) әйтте: “Менә шулай! Әмма Раббың: “Ул – Минем өчен бик җиңел эш. Без аны кешеләргә бер аять (дәлил) һәм Үзебездән бер рәхмәт итик дип (эшләячәкбез). Бу инде – карар кылынган бер эш”, – диде»** («Мәрьям», 21).

Җәнабел-Хак морадына ярашлы рәвештә:

فَحَمَلَتْهُ فَانْتَبَذَتْ بِهِ مَكَانًا قَصِيًّا

**«Ул (Мәрьям) (Гайсәгә) йөккә узды, аның (карынындагы бала) белән бергә ерак җиргә китте»** («Мәрьям», 22).

Хәзрәти Мәрьямнең тулгагы көчәя башлый. Ул бер корыган хөрмә агачы янына килеп, шуңа таяна. Аятьтә болай дип хәбәр ителә:

فَأَجَاءَهَا الْمَخَاضُ إِلَىٰ جِذْعِ النَّخْلَةِ قَالَتْ يَا لَيْتَنِي مِتُّ قَبْلَ هَٰذَا وَكُنْتُ نَسْيًا مَنْسِيًّا

**«Тулгак газабы аны (таянып торыр өчен) хөрмә агачы кәүсәсенә алып килде. Ул: “Аһ, элегрәк үлсә идем дә, һич онытылып беткән булса идем!” – диде»** («Мәрьям», 23).

Ниһаять, шул коры агач төбендә Гайсә галәйһис-сәләәм дөньяга килә. Аллаһ Тәгалә аны атасыз яралта. Чиксез кодрәт иясе булган Җәнабел-Хак, бөеклегенең бер чагылышы буларак, Адәм галәйһис-сәләәмне анасыз һәм атасыз рәвештә – туфрактан; Хәүва анабызны анасыз килеш – Хәзрәти Адәмнән; Гайсә галәйһис-сәләәмне исә атасыз рәвештә Мәрьям анабыздан яралта.

Хәзрәти Гайсәнең тууы белән Хәзрәти Адәмнең яратылышы арасында охшашлык бар, ул һәр ике очракта да яратылышның «Күн!», ягъни «Бул!» дигән әмер белән чынга ашуыннан гыйбарәт. Җәнабел-Хак әлеге хикмәтне аяти кәримәдә түбәндәгечә белдерә:

إِنَّ مَثَلَ عِيسَىٰ عِنْدَ اللهِ كَمَثَلِ آدَمَ خَلَقَهُ مِنْ تُرَابٍ ثُمَّ قَالَ لَهُ كُنْ فَيَكُونُ

**«Һичшиксез, Аллаһ хозурында Гайсәнең мисалы Адәмнең мисалы кебек ки, Ул аны туфрактан яралтты, шуннан аңа: “Бул!” – дип әйтте, һәм ул бар булды»** («Әли Гыймран», 59).

Бу аяти кәримә, Аллаһ кодрәтенең чиксезлеген дә, әүвәл шаккаткан яһүдиләрнең соңрак яудырган шакшы ялалары каршында Хәзрәти Мәрьямнең гыйффәтле икәнен дә белдерә.

Гайсә галәйһис-сәләәмнең дөньяга килү тарихы бернинди дә чыганакларда теркәлмәгән. Бер Инҗилдә дә бу мәсьәләгә кагылышлы мәгълүмат очрамый. Бары тик бер Инҗилдә генә Хәзрәти Гайсәнең яһүди король заманында туганлыгы языла (Матфей Инҗиле, 2/1), ләкин Рим чыганаклары ул корольнең миладигә кадәр үлгәнлеге турында белдерә. Димәк, барлык мондый аңлатмалар бер-берсенә ачыктан-ачык каршы килә. Шулай итеп, «Раштуа» дигән бәйрәмнең мәгънәсе дә уйлап чыгарылган нигезсез бер риваятьтән ерак китми. Шунлыктан хәзерге көндә католиклар Раштуа бәйрәмен 24–25 декабрь көннәрендә билгеләп үтсә, әрмән чиркәве аны 6 гыйнварда бәйрәм итә. Протестантларның бер өлеше исә, бу вакыйга турында изге язмаларда анык әйтелмәгәнлекне нигез итеп, Раштуаны бөтенләй бәйрәмгә санамый.

Хәзрәти Гайсә туганнан соң:

فَنَادَاهَا مِنْ تَحْتِهَا أَلَّا تَحْزَنِي قَدْ جَعَلَ رَبُّكِ تَحْتَكِ سَرِيًّا

**«Шулчак ул (Гайсә яки фәрештә) аның (Хәзрәти Мәрьямнең) аскы ягыннан дәште: “Кайгырма! Синең Раббың астыңда бер инеш яралтты”»** («Мәрьям», 24).

Бу аятькә мондый мәгънә дә бирелә:

«Борчылма! Раббың синең астыңдагыны (ягъни Гайсәне) шәрәфле юлбашчы итеп яралтты!»

Хәзрәти Мәрьямгә дәшкән тавыш болай дип дәвам итә:

وَهُزِّي إِلَيْكِ بِجِذْعِ النَّخْلَةِ تُسَاقِطْ عَلَيْكِ رُطَبًا جَنِيًّا

**«Хөрмә агачы кәүсәсен үзеңә таба селкет, өстеңә яңа өлгергән хөрмәләр төшсен!»** («Мәрьям», 25).

Хәзрәти Мәрьям хөрмә ботагын үзенә таба тартып китереп селкеткәч, кыш фасылы булуга карамастан, агач шундук хөрмә бирә башлый. Мәрьям, алдындагы арыктан су эчеп, яңа өзелгән хөрмәләрне ашый. Хәзрәти Мәрьямне юату өчен, агач шул рәвешле кыш көне җимеш бирә. Хәзрәти Мәрьямгә мондый әмер килә:

فَكُلِي وَاشْرَبِي وَقَرِّي عَيْنًا فَإِمَّا تَرَيِنَّ مِنَ الْبَشَرِ أَحَدًا
فَقُولِي إِنِّي نَذَرْتُ لِلرَّحْمٰنِ صَوْمًا فَلَنْ أُكَلِّمَ الْيَوْمَ إِنْسِيًّا

**«Аша, эч, шатлан! Әгәр дә кешеләрдән берәрсен күрсәң: “Мин Рахманга ураза нәзере әйттем. Бүген бер кеше белән дә сөйләшмәячәкмен”, – диген»** («Мәрьям», 26).

Риваятькә күрә, Хәзрәти Мәрьям кавемендә ашау-эчүдән тыелып ураза тотылган кебек, сөйләшмичә тору рәвешендәге ураза була. Яисә уразалы кеше ашау-эчүдән дә тыела, сөйләшүдән дә баш тарта.

Гайсә галәйһис-сәләәмнең дөньяга килүе кавем халкы арасында бик зур имеш-мимешләргә, төрле яла-гайбәтләргә юл ача. Аяти кәримәләрдә бу хәл түбәндәгечә искә алына:

فَأَتَتْ بِهِ قَوْمَهَا تَحْمِلُهُ قَالُوا يَا مَرْيَمُ لَقَدْ جِئْتِ شَيْئًا فَرِيًّا

**«Ниһаять, ул (Мәрьям) аны (Гайсәне кочагында) күтәреп кавеменә килде. Әйттеләр: “И, Мәрьям! Һичшиксез, син бик гаҗәп (җирәнгеч) эш эшләдең!”»** («Мәрьям», 27).

يَا أُخْتَ هَارُونَ مَا كَانَ أَبُوكِ امْرَأَ سَوْءٍ وَمَا كَانَتْ أُمُّكِ بَغِيًّا

**«И, Һарунның сеңлесе! Синең атаң яман кеше түгел иде. Анаң да зиначы булмаган иде»** («Мәрьям», 28).

Әлеге аятьтә телгә алынган Һарун Муса галәйһис-сәләәмнең туганы булган Һарун галәйһис-сәләәм түгел. Бу мәсьәләгә кагылышлы карашларның хаклыкка иң якынына күрә, сүз Хәзрәти Мәрьямнең бертуганы турында бара. Ул да әти-әнисе кебек гыйффәтле һәм изге бәндә була. Шуңа күрә кавеме мондый затның сеңлесе булган Мәрьямгә зина (!) кебек гөнаһның һич килешмәгәнлеген белдерергә тели.

Хәзрәти Мәрьям өстенә Исраил угыллары тарафыннан бертуктаусыз мыскыллау-кимсетүләр ява. Ул исә сабыр гына тыңлый, үзенә кушылганга буйсынып, берни сөйләшми. Тик кавеменең әхлаксыз гамәлләре шактый көчәя. Ниһаять, Аллаһның ярдәме килеп ирешә.

Аяти кәримәдә болай дип бәян ителә:

فَأَشَارَتْ إِلَيْهِ قَالُوا كَيْفَ نُكَلِّمُ مَنْ كَانَ فِي الْمَهْدِ صَبِيًّا

**«(Мәрьям) аңа (баланы) күрсәтте. Алар: “Ничек без бишектәге бала белән сөйләшик?” – диделәр»** («Мәрьям», 29).

Киләчәктә Аллаһның илчесе булачак Хәзрәти Гайсә Җәнабел-Хак тарафыннан бирелгән сөйләшү сәләте ярдәмендә телгә килә һәм бишектә килеш болай ди:

قَالَ إِنِّي عَبْدُ اللَّهِ آتَانِيَ الْكِتَابَ وَجَعَلَنِي نَبِيًّا

**«Һичшиксез, мин – Аллаһның (сайлап алынган) колы. Ул миңа Китап бирде һәм мине пәйгамбәр итте!»** («Мәрьям», 30).

وَجَعَلَنِي مُبَارَكًا أَيْنَ مَا كُنْتُ وَأَوْصَانِي بِالصَّلَاةِ وَالزَّكَاةِ مَا دُمْتُ حَيًّا

**«Ул мине кайда гына булса да мөбарәк бер кемсә итте. Исән чагымда миңа намазны һәм зәкятне әмер итте»** («Мәрьям», 31).

وَبَرًّا بِوَالِدَتِي وَلَمْ يَجْعَلْنِي جَبَّارًا شَقِيًّا

**«Анама карата да итагатьле (кылды). Мине тәкәббер һәм тискәре итмәде»** («Мәрьям», 32).

وَالسَّلَامُ عَلَيَّ يَوْمَ وُلِدْتُ وَيَوْمَ أَمُوتُ وَيَوْمَ أُبْعَثُ حَيًّا

**«Туган көнемдә дә, үләчәк көнемдә дә, тере булып (кабердән) чыгарылачак көнне дә миңа сәлам булсын»** («Мәрьям», 33).

Хәзрәти Гайсәнең бишектәге сабый хәлендә сөйләшә башлавы тирә-юньдәгеләрне шаккатыра. Шул рәвешле Хәзрәти Мәрьямнең гаепсезлеге раслана һәм ул кавеме каршында аклана.

Кяфер халыкның аннан: «Бу баланы каян алдың?» – дигән соравына каршы җавап буларак, Хәзрәти Мәрьям һәрвакыт әнә шулай итеп баласын күрсәтә һәм: «Бала үзе әйтсен!» – дип әйтә торган була. Гайсә галәйһис-сәләәм исә сабый килеш: «Минем әнием – намуслы, гыйффәтле хатын. И наданнар! Гыйффәтлелек һәм оят үрнәге булган әниемне гаепләмәгез! Белегез, Аллаһ Тәгалә мине атасыз рәвештә дөньяга китерде. Бу – Аллаһның бер могҗизасы!» – дип белдерә.

Шуннан соң бик күпләр: «Бу – Аллаһның аермачык могҗизасы. Чөнки яңа туган бер бала да бишектә килеш сөйләшә алмый. Чыннан да бу – Аллаһ тарафыннан җибәрелгән нәрсә. Җәнабел-Хакның бөеклеген күрсәтә торган бер вакыйга», – дип таныйлар.

Халыкның бер өлеше барыбер гаеп-яла ягудан туктамый. Аяти кәримәдә бу хакта болай диелә:

ذَلِكَ عِيسَى ابْنُ مَرْيَمَ قَوْلَ الْحَقِّ الَّذِي فِيهِ يَمْتَرُونَ

**«Менә бу – Мәрьям улы Гайсә. Ул Хакның сүзе буларак ки, алар аның хакында шөбһәләнәләр!»** («Мәрьям», 34).

Аятьтә Гайсә галәйһис-сәләәмнең «Хакның сүзе» дип телгә алынуы аның «Бул!» әмере нәтиҗәсендә барлыкка килүе белән бәйле. Әлеге хакыйкать башка аяти кәримәләрдә дә искә алына:

وَالَّتِي أَحْصَنَتْ فَرْجَهَا فَنَفَخْنَا فِيهَا مِنْ رُوحِنَا وَجَعَلْنَاهَا وَابْنَهَا آيَةً لِلْعَالَمِينَ

**«Гаурәт урынын саклаган хатынны да (Мәрьямне дә хәтерлә)! Без аның эченә рухыбыздан өрдек һәм аны да, улын да галәмнәр өчен бер билге иттек»** («әл-Әнбия», 91).

وَمَرْيَمَ ابْنَتَ عِمْرَانَ الَّتِي أَحْصَنَتْ فَرْجَهَا فَنَفَخْنَا فِيهِ مِنْ
رُوحِنَا وَصَدَّقَتْ بِكَلِمَاتِ رَبِّهَا وَكُتُبِهِ وَكَانَتْ مِنَ الْقَانِتِينَ

**«Гыймран кызы Мәрьямне дә ки (Аллаһ үрнәк күрсәтте), ул гаурәт җирен саклады. Без рухыбыздан аңа өрдек. Ул Раббысының сүзләрен һәм китапларын хак дип тапты һәм гыйбадәт кылучылардан булды»** («әт-Тәхрим», 12).

Хәзрәти Гайсәнең сабый килеш сөйләшүе бик күп яла-гаепләрнең юлын кисә, ялачыларның авызын яба. Тик бик тиздән кабат фетнәләр куба, яла ягулар башлана. Гафил кавем кешеләре: «Атасыз бала буламыни?!» – диешәләр. Аннары: «Бу зинаны Зәкәрийя генә кылган була ала!» – дип, Зәкәрийя галәйһис-сәләәм Бәйтел-Макдистә ялгыз калган бервакытта: «Син Мәрьям белән зина кылгансың!» – дигән яла ягып, аңа һөҗүм итәләр. Аларның явызлыгыннан сакланыр өчен, Зәкәрийя галәйһис-сәләәм бер агач куышына кача. Шайтан, кеше кыяфәтендә килеп чыгып, Зәкәрийя галәйһис-сәләәмне эзләүче кабахәтләргә, ул яшеренгән агачны күрсәтеп: «Шушы агачны пычкы белән икегә кисегез! Бернәрсә дә югалтмаячаксыз! Зәкәрийя шуның эчендә ул!» – дип котырта.

Явыз бәндәләр шундук агачны кисәргә керешә. Пычкы Зәкәрийя галәйһис-сәләәмнең башын яра башлаган мизгелдә, мәзлум пәйгамбәр «аһ!» дип әйтергә авыз ача, ләкин: «И, Зәкәрийя! Зарланма!» – дигән фәрман-өндәү килә. Зәкәрийя галәйһис-сәләәм ихлас буйсынучанлык һәм сабырлык күрсәтә һәм, пычкы белән икегә бүленеп, шәһид китә. Аллаһ катында ул бөек мәртәбәләргә ирешә.

Шулчакларда Хәзрәти Мәрьямнең бу вакыйгага хәтле ярәшкән егете Йосыф Нәҗҗарга да шундый ук гаеп атыла.

Зәкәрийя галәйһис-сәләәмне ерткычларча үтергән бәдбәхет яһүдиләр Хәзрәти Мәрьям белән аның улы Хәзрәти Гайсәгә бер-бер зыян салмасыннар өчен, Җәнабел-Хак аларны Үзенең ышанычлы сагына ала:

وَجَعَلْنَا ابْنَ مَرْيَمَ وَأُمَّهُ آيَةً وَآوَيْنَاهُمَا إِلَىٰ رَبْوَةٍ ذَاتِ قَرَارٍ وَمَعِينٍ

**«Мәрьям улы белән анасын да бер аять (кодрәтебез билгесе) иттек. Ул икәүне урнашу урыны итеп агымсулы бер калкулыкка сыендырдык»** («әл-Мүэминүн», 50).

Бу урынның Мисыр территориясендә булганлыгы риваять кылына. Хәзрәти Мәрьям белән Хәзрәти Гайсә анда унике ел яши. Шушы вакыт эчендә гаҗәп вакыйгалар күзәтелә. Беркөнне алар яшәгән өйдә бер өлкән агайның күп кенә акчасы югала. Бу өйдә бик ярлы-ябагай кешеләр гомер итә. Өлкән агай ул акчаны кем алганын аңлый алмый, шунлыктан һәркем шик астына эләгә. Бу хәл Хәзрәти Мәрьямне бик борчуга сала. Бу йортта яшәүчеләр арасында бер сукыр һәм бер гарип кеше була. Әнисенең бик кайгыруын күреп, Хәзрәти Гайсә шул ике кешегә: «Акчаны яшергән җирегездән чыгарыгыз!» – дип әйтә. Мондый ап-ачык могҗизага хәйран калып, карак бәндәләр алган акчаларын китереп бирергә мәҗбүр кала. Бу вакыйгадан соң Хәзрәти Гайсәнең халык каршында абруе шактый күтәрелә.

### Хәзрәти Гайсәнең пәйгамбәрлеге

Мисырда унике ел яшәгәч, Хәзрәти Гайсә Иерусалимгә кайтып, Насыйра бистәсенә төпләнә. Шуңа күрә христианнарны «нәсара, насрани» дип атыйлар да.

Хәзрәти Гайсәгә утыз яшендә пәйгамбәрлек вазифасы йөкләнә. Ул кичекмәстән бу вазифасын үтәргә – кешеләрне тәүхид дингә өндәргә керешә.

Аллаһ Тәгалә әйтә:

وَلَقَدْ أَرْسَلْنَا نُوحًا وَإِبْرَاهِيمَ وَجَعَلْنَا فِي ذُرِّيَّتِهِمَا النُّبُوَّةَ وَالْكِتَابَ فَمِنْهُمْ مُهْتَدٍ وَكَثِيرٌ مِنْهُمْ فَاسِقُونَ

**«Без Нухны һәм Ибраһимне җибәргән идек. Пәйгамбәрлекне һәм китапларны да икесенең нәселенә бирдек. Алардан (кешеләрдән) һидәят тапканнар бар, ләкин араларыннан күбесе – фасикълар»** («әл-Хәдид», 26).

Коръәни-Кәримдә исеме телгә алынган дүрт олуг китапның шулар нәселеннән килгән пәйгамбәрләргә иңдерелгәнлеге аңлашыла.

ثُمَّ قَفَّيْنَا عَلَىٰ آثَارِهِمْ بِرُسُلِنَا وَقَفَّيْنَا بِعِيسَى ابْنِ مَرْيَمَ وَآتَيْنَاهُ الْإِنْجِيلَ وَجَعَلْنَا فِي قُلُوبِ الَّذِينَ اتَّبَعُوهُ رَأْفَةً وَرَحْمَةً وَرَهْبَانِيَّةً ابْتَدَعُوهَا مَا كَتَبْنَاهَا عَلَيْهِمْ إِلَّا ابْتِغَاءَ رِضْوَانِ اللَّهِ فَمَا رَعَوْهَا حَقَّ رِعَايَتِهَا فَآتَيْنَا الَّذِينَ آمَنُوا مِنْهُمْ أَجْرَهُمْ وَكَثِيرٌ مِنْهُمْ فَاسِقُونَ

**«Шуннан соң аларның эзләреннән үк илчеләребезне җибәрдек. Мәрьям улы Гайсәне дә алар артыннан җибәрдек. Аңа Без Инҗилне бир-**

**дек һәм аңа ияргәннәрнең күңелләрендә мәрхәмәт һәм кызгану барлыкка китердек. Раһиблыкны исә алар уйлап чыгардылар. Без аны аларга фарыз кылмадык, бары тик Аллаһның ризалыгын казану өчен (үзләре шулай эшләделәр). Ләкин тиеш булганча аны үтәмәделәр. Һәм Без алар арасыннан иман китергән кешеләргә әҗерләрен бирдек. Алардан күбесе исә – фасикълар»** («әл-Хәдид», 27).

Монахлык христианнар соңыннан барлыкка китергән карашлар системасы һәм тормыш рәвеше булып тора. Риваятьләргә күрә, Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәмнән соң мөэминнәр явыз кяферләр тарафыннан кысрыклана, юк ителә башлый. Шул сәбәпле кабынган өч сугышта мөэминнәр бик авыр югалтулар кичерә. Яуда исән калган иман ияләре, үзләре дә үлә-нитә калсалар, дингә өндәргә кеше калмаячак дип борчылып, сугышмаска дигән карарга килеп, бары гыйбадәт белән генә шөгыльләнә башлый. Әнә шул рәвешле фетнәдән качып, диннәрендә ихласлык, эчкерсез бирелгәнлек күрсәткән әлеге кешеләр дөньяның бөтен ләззәтләреннән, артык ашау-эчүдән, өйләнүдән ваз кичә; тауларда, мәгарәләрдә, төрле куышларда һәм аулак биналарда гыйбадәт белән мәшгуль була. Тик халыкның күп өлеше аларга иярми, Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәмнең динен кире кага; хөкемдарларының динен кабул итеп, тәслис (өчаллалык) гакыйдәсен китереп чыгаралар; Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм пәйгамбәр итеп җибәрелгәч, аны да кире кагалар һәм башка шундый ялгыш юлларга кереп адашалар.

Гайсә галәйһис-сәләәм динне тәблигъ кылуын дәвам итә. Ләкин кешеләр көферлек мәсьәләсендә шулкадәр үҗәт, кире була...

Гайсә галәйһис-сәләәм бик күп могҗизалар күрсәтә. Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәмгә бирелгән Тәүратның хаклыгын раслый, әмма Аллаһ Тәгаләнең кайбер хөкемнәрне алыштыруы турында дәгъват кыла:

وَمُصَدِّقًا لِمَا بَيْنَ يَدَيَّ مِنَ التَّوْرَاةِ وَلِأُحِلَّ لَكُمْ بَعْضَ الَّذِي
حُرِّمَ عَلَيْكُمْ وَجِئْتُكُمْ بِآيَةٍ مِنْ رَبِّكُمْ فَاتَّقُوا اللَّهَ وَأَطِيعُونِ

**«(Гайсә әйтте:) “Миннән алда килгән Тәүратны дөресләүче (итеп) һәм сезгә харам кылынган нәрсәләрнең кайберләрен хәләл итүем өчен (җибәрелдем). Мин сезгә Раббыгыздан аять (могҗиза) алып килдем. Аллаһтан куркыгыз һәм миңа итагать итегез!”»** («Әли Гыймран», 50).

إِنَّ اللَّهَ رَبِّي وَرَبُّكُمْ فَاعْبُدُوهُ هَذَا صِرَاطٌ مُسْتَقِيمٌ

**«Һичшиксез, Аллаһ – минем дә Раббым, сезнең дә Раббыгыз. Аңа гыйбадәт кылыгыз, бу – туры юл»** («Әли Гыймран», 51).

وَإِذْ قَالَ عِيسَى ابْنُ مَرْيَمَ يَا بَنِي إِسْرَائِيلَ إِنِّي رَسُولُ اللَّهِ إِلَيْكُمْ مُصَدِّقًا لِمَا بَيْنَ يَدَيَّ مِنَ التَّوْرَاةِ وَمُبَشِّرًا بِرَسُولٍ يَأْتِي مِنْ بَعْدِي اسْمُهُ أَحْمَدُ فَلَمَّا جَاءَهُمْ بِالْبَيِّنَاتِ قَالُوا هَذَا سِحْرٌ مُبِينٌ

«Мәрьям улы Гайсә: “И, Исраил уллары! Мин – үземнән алдагы Тәүратны **дөресләүче һәм миннән соң киләчәк Әхмәд исемле бер рәсүл турында сөенечле хәбәр китерүче, Аллаһның сезгә җибәргән илчесемен”, – дигән иде. Ләкин ул аларга ап-ачык могҗизалар белән килгәч: “Бу бит – ап-ачык сихер!” – дигәннәр иде»** («әс-Сафф», 6).

Иоанн Инҗиленең 14 нче бүлегендә Гайсә галәйһис-сәләәмнең мондый сүзләре риваять кылына: «Мин Атадан сорармын, һәм Ул сезгә бүтән Яклаучы-Юатучы (Фараклит) бирәчәк, Ул сезнең белән мәңге булыр» (Иоанн Инҗиле, 14/16–17).

16 нчы бүлегендә исә болай диелә: «Әмма хак сүз әйтәм: Минем китүем сезнең өчен хәерлерәк. Мин китмәсәм, сезгә Яклаучы-Юатучы (Фараклит) килмәс, ә китсәм, Аны сезгә җибәрермен. Сезгә сөйлисе сүзләрем бик күп, әмма сез аларны хәзер кабул итә алмассыз. Ул хакыйкать Рухы килгәч, сезгә тулы хакыйкатькә юл күрсәтеп торыр. Ул сезгә Үзеннән түгел, бәлки ишеткәнен сөйләр һәм булачак хәлләрне белдерер» (Иоанн Инҗиле, 16/7, 12–13).

«Фараклит» сүзе «хәмед, мактау, рәхмәт» мәгънәсендә кабул ителә. Кайбер христианнар моны «мухаллис» (коткаручы) дигән мәгънәдә аңлата; кайберләре «хәммәд» һәм «хәмид» дип тәфсир кыла. Моның исә «Фараклит» сүзенең Әхмәд һәм Мөхәммәд мәгънәләренә туры килгән асыл исемгә ишарәләгәне бик ачык аңлашыла.

Варнава Инҗиленең 97 нче бабында мондый бер әңгәмә китерелә:

«Син сөйләгән Мәсихнең исеме ничек һәм Аның килгәнен каян аңлаячакбыз?» – дигән апостолларына Хәзрәти Гайсә болай диде: «Мәсихнең (Рәсүлнең) исеме хәйран калырлык дәрәҗәдә матур. Җәнабел-Хак Аның нурын яралткан вакытта, Аңа шушы исемне бирде һәм Аны күкләрнең бөеклеге эченә куйды, Аннары: “Синең хөрмәткә Мин җәннәтне, дөньяны һәм бик күп мәхлукларны яралттым. Боларның барысын да Сиңа бүләк итәм. Сиңа ияргән Миннән нигъмәт табачак; Сине кире кагучы Минем тарафымнан ләгънәтләнәчәк. Мин Сине дөньяга Үземнең Рәсүлем итеп җибәрәчәкмен. Синең сүзең бары хакыйкать кенә булачак. Җир һәм күк юкка чыга ала, ләкин Синең иманың һәрчак мәңгелек булачак”. Аның исеме Әхмәд».

Шуннан соң Гайсә галәйһис-сәләәм тирәсендә җыелган мөэминнәр шундук: «И Әхмәд! Дөньяны коткару өчен тизрәк кил!» – дия-дия кычкырып ялвара башладылар».[168]

168. Моңа охшаш мәгълүмат өчен Варнава Инҗиленең 39 һәм 41 нче бабларын да карарга мөмкин.

Кяферләрнең Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләамгә карата ачу-нәфрәте көннән-көн көчәя бара. Моны аңлаган Гайсә галәйһис-сәләам, үзенә ышанганнар арасында сайлап алган унике мөэминнән, ягъни апостолларыннан: «Аллаһ Җәллә Җәләлүһүнең диненә хезмәттә һәм аны саклауда кем минем ярдәмчем булачак?» – дип сорый.

Хәвариләрнең барысы берьюлы: «Без синең ярдәмчеләрең. Һәрнәрсәбез белән Аллаһ юлында ярдәмче булачакбыз, чөнки без күңелебезне Аның диненә бирдек. Син шаһит бул: без -синең динеңә бәйле чын мөселманнар!» – дип белдерә.

Аяти кәримәләрдә әйтелә:

فَلَمَّا أَحَسَّ عِيسَىٰ مِنْهُمُ الْكُفْرَ قَالَ مَنْ أَنْصَارِي إِلَى اللهِ
قَالَ الْحَوَارِيُّونَ نَحْنُ أَنْصَارُ اللهِ آمَنَّا بِاللَّهِ وَاشْهَدْ بِأَنَّا مُسْلِمُونَ

**«Гайсә аларда (кабахәт кешеләрдәге) көферлекне сизгәч: “Кемнәр Аллаһка (бару юылнда) ярдәмчеләрем?” – дигән иде. Хәвариләр әйтте: “Без – Аллаһның ярдәмчеләре. Без Аллаһка иман китердек. Шаһит бул: без – мөселманнар”»** («Әли Гыймран», 52).

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُونُوا أَنْصَارَ اللهِ كَمَا قَالَ عِيسَى ابْنُ مَرْيَمَ لِلْحَوَارِيِّينَ مَنْ
أَنْصَارِي إِلَى اللهِ قَالَ الْحَوَارِيُّونَ نَحْنُ أَنْصَارُ اللهِ فَآمَنَتْ طَائِفَةٌ مِنْ بَنِي إِسْرَائِيلَ
وَكَفَرَتْ طَائِفَةٌ فَأَيَّدْنَا الَّذِينَ آمَنُوا عَلَىٰ عَدُوِّهِمْ فَأَصْبَحُوا ظَاهِرِينَ

**«И, иман китерүчеләр! Аллаһның ярдәмчеләре булыгыз. Мәрьям улы Гайсә хәвариләренә: “Аллаһка (бару юлында) ярдәмчеләрем кем?” – дигән иде. Хәвариләр: “Без – Аллаһның ярдәмчеләре!” – диделәр. Исраил улларыннан бер таифә[169] ышанды, башка фирка инкяр итте. Без иман китергәннәрне дошманнарына каршы куәтләндердек, һәм алар җиңүчеләр булдылар»** («әс-Сафф», 14).

«Хәвари» (апостол) сүзе гарәп теленә эфиоп теленнән кергән, сүзнең тамыры – «хәварйа» «ярдәмче» дигән мәгънә белдерә. Шулай ук «сайлап алынган кеше» дигәнне дә белдерә.

Гайсә галәйһис-сәләамгә иң башта ук иман китергән һәм аңа булышкан унике ихлас һәм пакь мөэминне хәвариләр (апостоллар) дип атыйлар. Аларны «әнсаруллаһ» дип тә йөртәләр. Хәвариләр, христиан динен тарату өчен, Гайсә галәйһис-сәләам тарафыннан сайлап алына. Атаклы Варнава Инҗилен язган Варнава да шуларның берсе.

169. Таифә – кешеләр төркеме.

**Күктән табын төшү (Маидә)**

Хәвариләр, күктән сыйлы табын иңсен, дип, Хәзрәти Гайсәдән дога кылуын үтенә. Гайсә галәйһис-сәләәм: «Аллаһның кодрәтеннән шикләнәсез-ме? Мондый нәрсә сорарга ничек җөрьәт итәсез?» – дип сорый.

Хәвариләр: «Бүтән максатыбыз юк. Аллаһ Җәллә Җәләлүһүнең рәхмәтенә ирешү һәм тагын да ныграк инану өчен шундый бер табын сорадык!» – диде.

Гайсә галәйһис-сәләәм, госел алып, ике рәкәгать намаз укый. Үзенең түбәнчелеген күрсәтү өчен, өстенә иске кием киеп, Аллаһка ялвара. Бу табын һәм илаһи нигъмәт көнен бер бәйрәмгә әйләндерүне Җәнабел-Хактан сорый.

Дога кабул ителә һәм «маидә» (табын) иңә. Анда кыздырылган балык була. Балыкның баш очында тоз, койрык ягында серкә тора, табын яшел тәмләткечләр белән бизәлгән. Икмәк өстенә зәйтүн, бал, сыр һ.б.ш куелган була.

Хәвариләр бу юлы: «И, Аллаһның пәйгамбәре! Бу могҗиза эчендә дә бер могҗиза күрсәт!» – ди. Гайсә галәйһис-сәләәм табындагы балыкка: «Әй, балык! Галәмнәр Раббысының рөхсәте белән, терел!» – дип әйтә. Балыкка җан керә. Хәвариләрне курку биләп ала. Шуннан соң Гайсә галәйһис-сәләәм: «Әй, балык! Раббымның рөхсәте белән, әүвәлге хәлеңә кайт!» – дип боера. Балык элекке рәвешенә кайта. Хәвариләр Хәзрәти Гайсәгә: «И, Рухуллаһ! Башта сез ашагыз!» – дип тәкъдим итә.

Гайсә галәйһис-сәләәм исә: «Юк! Кемнәр сораган, шулар ашасын!» – дип боера.

Хәвариләрдә ниндидер курку барлыкка килә. Моны күргәч, Гайсә галәйһис-сәләәм: «Фәкыйрьләр һәм авырулар килсеннәр, шулар ашасын!» – дип белдерә.

Шундук ярлы-ябагайга һәм авыруларга хәбәр салалар. Мең өч йөз кеше килеп, шушы табыннан ашаса да, балык бетми. Бөтен ашаган бәндәләр ризыктан шифа таба, ашамаганнар исә бик үкенә.

Башка бер риваятькә күрә, Гайсә галәйһис-сәләәм апостолларга утыз көн ураза тотарга куша. Уразаларын тәмамлагач, кылган гыйбадәтләре кабул булдымы-юкмы икәнлегенә инану өчен, алар күктән бер табын иңдерүен, ул көннең бәйрәм ителүен, өстәлдәге ризыкның ярлы-бай – һәркемгә җитүен сорап, Хәзрәти Гайсәгә мөрәҗәгать итәләр.

Гайсә галәйһис-сәләәм аларның мондый үтенечкә тиешенчә шөкер итә алачагына шикләнеп борчыла һәм, апостолларга үгет-нәсыйхәт биреп, бу теләкләреннән баш тартырга тырыша. Тик апостоллар теләкләреннән ваз кичмәгәч, Гайсә галәйһис-сәләәм намазлыкка баса, ә хәвариләр артка тезелә. Рухуллаһ Җәнабел-Хакка ялварып, елый башлый. Гыйбадәт-догасы бетүгә, Аллаһның бер рәхмәте буларак, күктән маидә (табын) иңә. Аны чалмалы ике

зат күтәреп бара. Бу табын газап түгел, рәхмәт булсын өчен, Гайсә галәйһис-сәләәм дога кыла.

Күктән иңгән табын якыная һәм Гайсә галәйһис-сәләәм алдында туктый. Хәзрәти Рухуллаһ:

بِسْمِ اللَّهِ خَيْرِ الرَّازِقِينَ

– дип, ашъяулыкны күтәреп ала. Аның астында җиде балык, җиде җәймә, серкә, анар һәм башка җиләк-җимешләр була.

Табын көн саен иңә башлый. Бу хәл кырык көн дәвам итә. Табын иртән кояш чыкканнан соң иңә, ярлы-бай һәркем ашагач, өйлә вакытында күккә күтәрелә, шул чакта җиргә күләгәсе төшә.

Соңрак: «Байлар һәм сау-сәламәт кешеләр ашамасын!» – дигән вәхи килә. Әлеге боерык күңеле пычранган бай һәм нык бәндәләрнең ачуын китерә. Алар, нәфесләренә буйсынып, табыннан мәхрүм калганлыкларына ярсып: «Сез бу табынны чын дип уйлыйсызмы әллә?» – дип, башкаларны мыскыллый башлыйлар.

Алар утыз яки өч йөз утыз кеше була, илаһи газапка дучар ителеп, бер төндә дуңгызга әйләнәләр. Алар Хак Тәгалә белдереп куйган газапка тотыла. Бүтән кешеләр исә, алар белән булган хәлне күреп, куркуга төшә.

Дуңгызга әверелгәннәр, Гайсә галәйһис-сәләәмне күргәч, аннан ярдәм сорый – аның тирәсендә бөтерелеп йөреп, үтенү-ялваруны белдергән хәрәкәтләр ясыйлар. Гайсә галәйһис-сәләәм аларга исемнәре белән дәшкәч, елыйлар; башлары белән ымлап, ярдәм сорыйлар. Ләкин бик зур көферлеккә төшкәнгә күрә, бу газапка лаеклы тотылган булып, өч көннән соң тәмам һәлак ителәләр. Хәтта исләре дә калмый.

Риваятькә күрә, Гайсә галәйһис-сәләәм юлда бер дуңгызны очрата. «Исән-сау килеш юлдан чыгып кит!» – ди ул хайванга. Пәйгамбәрнең әйләнә-тирәсендәгеләр: «Моны шушы дуңгызга әйтәсеңме?» – дип сорый.

Гайсә галәйһис-сәләәм исә: «Мин телемнең әшәке нәрсәләргә күнегүеннән куркам», – дип әйтә.

Табын иңдерелү вакыйгасы Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә бәян кылына:

إِذْ قَالَ الْحَوَارِيُّونَ يَا عِيسَى ابْنَ مَرْيَمَ هَلْ يَسْتَطِيعُ رَبُّكَ أَنْ يُنَزِّلَ
عَلَيْنَا مَائِدَةً مِنَ السَّمَاءِ قَالَ اتَّقُوا اللَّهَ إِنْ كُنْتُمْ مُؤْمِنِينَ

**«Хәвариләр: "И, Мәрьям улы Гайсә! Раббыңның безгә күктән бер табын иңдерергә көче җитәме?" – дигән иделәр. Ул: "Әгәр иман китергән кешеләр булсагыз, Аллаһтан куркыгыз", – дигән иде»** («әл-Маидә», 112).

قَالُوا نُرِيدُ أَنْ نَأْكُلَ مِنْهَا وَتَطْمَئِنَّ قُلُوبُنَا وَنَعْلَمَ أَنْ قَدْ صَدَقْتَنَا وَنَكُونَ عَلَيْهَا مِنَ الشَّاهِدِينَ

**«(Ләкин) алар: “Аннан ашап, күңелләребезнең тынычлануын һәм синең безгә дөресен сөйләгәнеңне белүебезне һәм моңа (үз күзләре белән күреп) шаһитлык итүчеләрдән булуыбызны телибез”, – дигәннәр иде»** («әл-Маидә», 113).

قَالَ عِيسَى ابْنُ مَرْيَمَ اللَّهُمَّ رَبَّنَا أَنْزِلْ عَلَيْنَا مَائِدَةً مِنَ السَّمَاءِ تَكُونُ
لَنَا عِيدًا لِأَوَّلِنَا وَآخِرِنَا وَآيَةً مِنْكَ وَارْزُقْنَا وَأَنْتَ خَيْرُ الرَّازِقِينَ

**«(Шуннан соң) Мәрьям улы Гайсә: “И Аллаһ! И, Раббыбыз! Безгә күктән бер табын иңдер ки, безнең өчен һәм әүвәлгеләребез, һәм соңгыларыбыз өчен бер бәйрәм һәм Синнән бер аять (могҗиза) булсын һәм Син безне ризыкландыр. Ризык бирүчеләрнең иң яхшысы Син бит”, – дип әйтте»** («әл-Маидә», 114).

قَالَ اللَّهُ إِنِّي مُنَزِّلُهَا عَلَيْكُمْ فَمَنْ يَكْفُرْ بَعْدُ مِنْكُمْ
فَإِنِّي أُعَذِّبُهُ عَذَابًا لَا أُعَذِّبُهُ أَحَدًا مِنَ الْعَالَمِينَ

**«Аллаһ: “Һичшиксез, Мин аны сезгә иңдерәчәкмен, әмма арагыздан кем дә кем аннан соң кяфер булса, Мин аны галәмнәрдән һичберсен җәзаландырмаган бер газап белән җәзага дучар итәчәкмен”, – диде»** («әл-Маидә», 115).

Аяти кәримәләрдән аңлашылганча, апостолларның сыйлы табын соравы йөрәкләрен тәмам инандыру теләге белән бәйле, күңелләрендә шөбһә бар дигән сүз түгел. Алар берәр илаһи могҗизаны үз күзләре белән күрергә тели. Ләкин мондый сорау бик зур җаваплылык та таләп итә, шунлыктан Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәм : «Әгәр мөэмин икәнсез, Аллаһтан куркыгыз!» – дип кисәтә.

Монда ике мәсьәлә игътибарга лаек:

1. Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәм: «Анык билге-үзенчәлекләрен билгеләп, могҗиза сорауда Аллаһтан куркыгыз!» – дип кисәтә, чөнки могҗизаны үз теләгеңә күрә сорау хата һәм чиктән ашу булып санала. Шулкадәр могҗиза күргән килеш тә, мондый нигезсез, хөрмәтсез кыюлык белән, кабат-кабат могҗиза сорау һич урынсыз. Мондый гамәл иман китергән бәндәгә бөтенләй килешми. Чиктән ашкан теләк бәндәнең буйсынучанлыгын, иманын йомшартырга мөмкин.

2. Икенче яктан караганда, Гайсә галәйһис-сәләәм апостолларына: «Әгәр мөэмин икәнсез, Аллаһтан куркыгыз!» – дип, теләкләре чынга ашсын өчен, тәкъва булырга кирәклеген белдерә.

Гаммар ибне Ясир радыйаллаһу ганһедән тапшырылган бер хәдис-шәрифтә болай дип риваять кылына:

*«Күктән өстәл иңә. Анда икмәк һәм ит була. Ашаучыларга хыянәт итмәскә, сакларга алып калмаска һәм иртәгәсе көн өчен ризык аерып куймаска боерыла. (Ләкин) алар (бу әмерне) тыңламый һәм аңа хыянәт юлына баса. (Табындагы ризыкларны) сакларга алып калалар. Шуннан соң маймыл һәм дуңгызга әйләндереләләр»* (Тирмизи, «Тәфсир», 5/3061).

**Хәвариләрнең һәм Гайсә галәйһис-сәләәмнең Нусайбингә китүе**

Сәлман Фариси радыйаллаһу ганһедән мондый риваять тапшырыла:

Гайсә галәйһис-сәләәмгә Нусайбиндәге тәкәбберлеге, явызлыгы белән танылган бер хөкемдарны иманга өндәү йөкләнә. Ул үзеннән алда анда берничә хәвариен җибәрергә уйлый. Алардан: «Кайсыгыз барачак?» – дип сорый.

Ягъкуб: «Мин барам», – ди. Аңа Тәвман белән Шәмгун да кушыла. Шәмгун Хәзрәти Гайсәгә: «И, Рухуллаһ! Сезнең рөхсәтегез белән мин дә барыйм, тик авыр хәлдә калып, сезне чакырсам, караш һәм ярдәмегездән ким кылмагыз!» – дип үтенә.

Өчәүләп юлга чыгалар. «Ярдәм сорасагыз, мин килермен», – дип, Шәмгун шәһәр читендә кала. Ягъкуб һәм Тәвман калага юл тота. Алар халыкны җыеп, тәүхид гакыйдәсен кабул итәргә өнди. Хәзрәти Мәрьям белән Гайсә галәйһис-сәләәм турындагы ялганнарга ышанганга күрә, халык, бу чакыруны кире кагып, бәхәс куптара, хәтта хәвариләргә ләгънәт яудыра. Аннары Тәвманны хөкемдар каршына алып киләләр. Патша аның аяк-кулларын чаптыра, кызган тимер белән күзләрен сукырайтып, төрмәгә аттыра.

Шулвакыт Шәмгун, үзенең кем икәнлеген белдермичә, шәһәргә керә һәм хөкемдарның ышанычын яулый. Аның белән бик якын дуслашып китә, һәрвакыт гәпләшеп йөри торган иптәшенә әйләнә. Беркөнне Шәмгун, Тәвманнан сорыйсы нәрсәләре барлыгын белдереп, хөкемдардан рөхсәт бирүен үтенә. Шәмгун белән Тәвман бер-берсен белмәгән-танымаган булып кылана.

Шәмгун: «Әй, бәндә! Ни әйтәсең?» – дип сорый. Тәвман: «Гайсә галәйһис-сәләәм – Аллаһның колы һәм рәсүле», – ди. Аннары әңгәмәләре болай дәвам итә: «Сүзеңнең дөреслеген ни белән дәлиллисең?» «Ул һәр авыруга шифа таба». «Моны табиблар да эшли. Башка дәлилең бармы?» «Халыкның өйләрендә ни ашаганын, ни саклаганын белә». «Моны тылсымчылар, каһиннәр дә белә. Тагын дәлилең бармы?». «Балчыктан кош ясап, шуны очырып җибәрә». «Моны сихерчеләр дә эшли. Тагын ни әйтерсең?» «Үлеләрне терелтә!..» «Менә монысы кеше табигатенең аръягындагы бернәрсә. Алайса Гайсәне чакырыйк. Чыннан да үлеләрне терелтә икән, аңа иман китерик!»

Хөкемдар Шәмгунның бу сүзен хуплый. Шундук хәбәр җибәрелә һәм әлеге чакыру белән Гайсә галәйһис-сәләәм Нусайбингә килә. Ул Шәмгунны белгәнен сиздерми.

Шәмгун хөкемдарга: «Теләсәгез, аны Тәвман белән сыныйк», – дип тәкъдим итә.

Тәвманны алып киләләр. Гайсә галәйһис-сәләәм Тәвманның аяк-кулларын сыйпауга, бар гәүдәсе әүвәлге хәленә кайта. Аннары пәйгамбәр кулы белән Тәвманның күзләрен сөртеп ала, алар да төзәлә.

Шәмгун, хөкемдарга карап: «Болар чыннан да пәйгамбәрлеккә бер дәлил бит», – ди. Аннары ул: «Әй, Гайсә! Шушы мәҗлесебездә катнашучылар бу төндә өйләрендә ни ашады, нәрсәне саклап куйды?» – дип сорый. Гайсә галәйһис-сәләәм аерым-аерым һәркемнекен әйтеп чыга.

Шәмгун аңа балчыктан ярканат ясарга тәкъдим итә – аны да ясап очыра. Авырулар өчен шифа сорый – бөтен чирлеләр савыга. Берәр үлене терелтүен тели. Терелтеләчәк кеше дип, Нух галәйһис-сәләәмнең улы Сам билгеләнә. Гайсә галәйһис-сәләәм, Аллаһның рөхсәте белән, Сам ибне Нухны да терелтә. Самнан: «Үлгән чагыңда шушылай карт идеңме?» – дип сорыйлар. Ул: «Юк! Терелткәндә, кыямәт купкан икән, дип уйладым!..» – дип җавап бирә. Шуннан соң Сам ибне Нух, Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәмнең пәйгамбәрлеген раслап, янә үлә.

Бу кадәр күп һәм ап-ачык могҗизалар каршында хөкемдар һәм аның гаскәрләре барысы берьюлы иман китерә.

Моннан аңлашылганча, мөселманнарның акыллы, зирәк булулары һәм алдан күреп эш йөртүләре таләп ителә, чөнки хакыйкатьне һәр җирдә сөйләп йөрмичә, моның өчен нигез хәзерләргә, вакытын көтәргә кирәк.

### Хәбиб ән-Нәҗҗар

Гайсә галәйһис-сәләәм Антакья ягына ике хәварине җибәрә. Алар кешеләрне, потларга табынудан баш тартып, иманга килергә чакыра. Ләкин анда бер потпәрәст король була һәм ул әлеге ике хәварине эләктереп, зинданга яптыра. Шуннан соң Гайсә галәйһис-сәләәм хәвариләрнең башлыгы булган Шәмгунны җибәрә.

Шәмгун әүвәл король белән якын мөнәсәбәт кора, аның ышанычын яулый. Король һәм аның тирәсендәгеләргә уңай йогынты ясауга һәм үз сүзен үткәрүдә шактый уңышка ирешкәннән соң, аларны күркәм рәвештә иманга чакыра. Король һәм аның якыннары бу тәкъдимгә күңел биреп, иман китерәләр. Әмма халык иманга килергә теләми. Кешеләрнең шул рәвешле киреләнүе турында ишеткәч, Хәбиб ән-Нәҗҗар исемле берәү шәһәрнең ерак почмагындагы өеннән йөгерә-чаба килеп җитә. Бу илчеләр сөйләгәннәргә

үзенең инанганлыгын белдереп, ул бар халыкны иманга чакыра. Ләкин гафил бәндәләр аңа колак салмый, ташып чыккан ачуларын тыя алмыйча, Хәбиб ән-Нәҗҗарны үтереп ташлыйлар.

Әлеге вакыйга Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә аңлатыла:

وَاضْرِبْ لَهُمْ مَثَلًا أَصْحَابَ الْقَرْيَةِ إِذْ جَاءَهَا الْمُرْسَلُونَ

**«Аларга шәһәр халкын мисал итеп китер. Менә аларга җибәрелгәннәр (илчеләр) килгән иде»** («Йәсин», 13).

إِذْ أَرْسَلْنَا إِلَيْهِمُ اثْنَيْنِ فَكَذَّبُوهُمَا فَعَزَّزْنَا بِثَالِثٍ فَقَالُوا إِنَّا إِلَيْكُمْ مُرْسَلُونَ

**«Ул вакытта Без аларга икене (илче) җибәргән идек. Алар исә аларны ялганчылар дип санадылар. Без өченче (илче) белән куәтләдек. Алар: “Һичшиксез, без – сезгә җибәрелгән кешеләрбез”, – диделәр»** («Йәсин», 14).

قَالُوا مَا أَنْتُمْ إِلَّا بَشَرٌ مِثْلُنَا وَمَا أَنْزَلَ الرَّحْمٰنُ مِنْ شَيْءٍ إِنْ أَنْتُمْ إِلَّا تَكْذِبُونَ

**«Әйттеләр (илчеләргә): “Сез безнең кебек кешеләр генә. Рахман бернәрсә дә иңдермәде. Сез ялган сөйлисез!”»** («Йәсин», 15).

قَالُوا رَبُّنَا يَعْلَمُ إِنَّا إِلَيْكُمْ لَمُرْسَلُونَ

**«Алар (илчеләр) әйттеләр: “Раббыбыз белә: без, һичшиксез, сезгә җибәрелгән кешеләр”»** («Йәсин», 16).

وَمَا عَلَيْنَا إِلَّا الْبَلَاغُ الْمُبِينُ

**«Безгә ачык бер рәвештә (Аллаһның боерыкларын) сезгә ишеттерүдән башка берни йөкләнмәде»** («Йәсин», 17).

قَالُوا إِنَّا تَطَيَّرْنَا بِكُمْ لَئِنْ لَمْ تَنْتَهُوا لَنَرْجُمَنَّكُمْ وَلَيَمَسَّنَّكُمْ مِنَّا عَذَابٌ أَلِيمٌ

**«(Ләкин) алар (гафилләр): “Һичшиксез, без сездән шикләнәбез. Әгәр дә сез ваз кичмәсәгез, сезне ташлар атып үтерәчәкбез һәм бездән сезгә тилмерткеч бер газап кагылачак”, – диделәр»** («Йәсин», 18).

قَالُوا طَائِرُكُمْ مَعَكُمْ أَئِنْ ذُكِّرْتُمْ بَلْ أَنْتُمْ قَوْمٌ مُسْرِفُونَ

**«Алар (илчеләр) әйттеләр: “Сезнең шикләнүегез сезнең үзегездә. Сезгә үгет бирелде дипме (шикләнәсезме)? Әйе, сез чиктән ашкан халык шул”»** («Йәсин», 19).

وَجَاءَ مِنْ أَقْصَى الْمَدِينَةِ رَجُلٌ يَسْعَىٰ قَالَ يَا قَوْمِ اتَّبِعُوا الْمُرْسَلِينَ

**«Шәһәрнең читеннән йөгерә-йөгерә бер кеше килде һәм әйтте: “И, кавемем! Бу илчеләргә иярегез”»** («Йәсин», 20).

اتَّبِعُوا مَنْ لَا يَسْأَلُكُمْ أَجْرًا وَهُمْ مُهْتَدُونَ

**«Сездән түләү сорамаган кешеләргә иярегез, чөнки алар – туры юлга (һидәяткә) ирешүчеләр»** («Йәсин», 21).

Мондый киңәше аркасында, ул кешегә борылып: «Һай, син дә аларның диненнәнме?!» – дип сорыйлар. Моңа җавап итеп, ул кеше болай ди:

وَمَا لِيَ لَا أَعْبُدُ الَّذِي فَطَرَنِي وَإِلَيْهِ تُرْجَعُونَ

**«Нишләп мин үземне юктан бар итүчегә гыйбадәт кылмыйм? Сез дә бит Аңа кайтарылачаксыз»** («Йәсин», 22).

أَأَتَّخِذُ مِنْ دُونِهِ آلِهَةً إِنْ يُرِدْنِ الرَّحْمَٰنُ بِضُرٍّ لَا تُغْنِ عَنِّي شَفَاعَتُهُمْ شَيْئًا وَلَا يُنْقِذُونِ

**«Аны калдырып, үземә илаһлар алыйммы әллә? Әгәр Рахман миңа берәр зарар теләсә, аларның (потларның) шәфәгатьләре миңа ярдәм итә алмас, алар мине коткара алмаслар»** («Йәсин», 23).

إِنِّي إِذًا لَفِي ضَلَالٍ مُبِينٍ

**«Ул чакта мин ап-ачык бер адашу эченә төшкән булырмын»** («Йәсин», 24).

إِنِّي آمَنْتُ بِرَبِّكُمْ فَاسْمَعُونِ

**«Һичшиксез, мин Раббыгызга иман иттем, мине тыңлагыз!»** («Йәсин», 25).

Әмма азгын, кабахәт төркем, бу сүзләрне тыңламыйча, ул кешенең өстенә таш яудыра. Үлем алды мизгелендә Хәбиб ән-Нәҗҗарга хәбәр ирештерелә:

قِيلَ ادْخُلِ الْجَنَّةَ قَالَ يَا لَيْتَ قَوْمِي يَعْلَمُونَ بِمَا غَفَرَ لِي رَبِّي وَجَعَلَنِي مِنَ الْمُكْرَمِينَ

**«Аңа: “Кер җәннәткә!” – дип әйтелде. Ул (шуннан соң) әйтте: “Аһ, кавемем белсә иде! Раббымның мине гафу иткәнен һәм хөрмәт ителгәннәрдән (нигъмәткә лаек булганнардан) кылганын!”»** («Йәсин», 26–27).

Әбү Мөҗаһид Хәзрәтләре: «Мәхлукларның иң ахмагы – нәфес, чөнки гел үзенә зыянга булган нәрсәләр сорый», – дип әйтә.

Кабахәт бәндәләр исә шәһид киткән Хәбибән-Нәҗҗарның игелекле чакыруын кабул итми, нәфесләренең теләк-омтылышларына туры килмәгәнгә күрә, аны бөтен бәхетсезлекләрдә гаеплиләр. Югыйсә Хәбиб ән-Нәҗҗар аларның дөньялыкта һәм ахирәттә сау-сәламәт, бәхетле булуын теле. Тик кире халык, нәфескә буйсынып, иманга килүдән баш тарта һәм шул рәвешле ахирәт тормышларын һәлак итәләр.

**Гайсә галәйһис-сәләәмнең күккә күтәрелүе**

Муса галәйһис-сәләәмгә җибәрелгән дингә Бәни Исраил илтифатсыз мөнәсәбәт күрсәтә, төрлечә каршылык чыгара, туры юлдан тәмам читкә тайпыла. Аннан соң килгән пәйгамбәрләр, кавемне һәрдаим кисәтеп торсалар да, азгын халык барыбер төзәлмичә, явызлык, көч куллану юлын сайлый. Хәтта пәйгамбәрләрне үтерү кебек чиктән ашкан золым кылуга кадәр барып җитеп, Аллаһ илчеләренең җанын кыялар.

Гайсә галәйһис-сәләәм пәйда булганда, бу кавем шундый таркау, түбән хәлдә гомер кичерә. Алар берәр коткаручы көтә һәм әлеге көтелгән пәйгамбәрнең бик көчле, тоткан җирдән сындыра торган, көрәшче рухлы шәхес булуын тели, чөнки ул пәйгамбәр аларны тоткынлыктан чыгарып, дөньялыкта бик зур мөмкинлекләргә юл ачарга тиеш дип санала. Шуңа күрә аларны һидәяткә чакырыр өчен Гайсә галәйһис-сәләәм җибәрелгәч, яһүдиләр бу кешене бик йомшак холыклы, көчсез дип кабул итә һәм аңа инанырга теләми.

Ләкин Гайсә галәйһис-сәләәм, һичнигә карамастан сабырлык күрсәтеп, җир йөзендә тынычлык һәм иминлек урнаштыру, кешеләр арасында мөнәсәбәтләрне яхшыртып, аларны татулаштыру өчен күп көч куя. Яһүдиләрне алар кереп киткән ялгыш юлдан коткарырга тырыша. Тик куллары пәйгамбәрләр канына буялган азгын яһүдиләр иманга чакыруны ошатмый. Нәтиҗәдә, Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәмне үтерергә карар бирәләр. Шул рәвешле Гайсә галәйһис-сәләәмгә дә, аның тирәсендәгеләргә дә төрлечә явызлык кыла башлыйлар. Аларның золымы шул дәрәҗәгә җитә ки, күргән газап-җәфалар аркасында хәвариләрдән Юдас, Исхар һәм Йот (Йәһуда) диннәреннән ваз кичә. Өстәвенә, болар арасыннан Йәһуда Зәкәрийя һәм Яхъя галәйһимәс-сәләмне үтергән кансыз яһүдиләргә Гайсә галәйһис-сәләәмнең кайда яшәве турында хәбәр итә. Ләкин бу хәвари Җәнабел-Хак газабына тарый һәм, кылган гамәленең җәзасы буларак, рәхимсез яһүдиләргә Гайсә галәйһис-сәләәм кыяфәтендә күрсәтелә һәм хач рәвешендәге дар агачына кадаклана. Гайсә галәйһис-сәләәм исә күккә күтәрелә.

Гайсә галәйһис-сәләәмнең күккә ашуы турында төрле карашлар бар.

Ибне Габбас радыйаллаһу ганһүмәдән тапшырылган риваятькә күрә, бер төркем яһүдиләр Гайсә галәйһис-сәләәм һәм аның анасы Хәзрәти Мәрьямне төрлечә мыскыллый. Хәзрәти Гайсә: «Йә, Раббы! Син мине “Күн! – Бул!” сүзе белән бар иттең. Миңа һәм анама тел тидергәннәргә ләгънәтең булсын!» –

дип, кулларын күтәреп дога кыла. Бу доганы кабул кылып, Аллаһ Тәгалә яла ягучыларны һәм мыскыллап көлүчеләрне маймылга һәм дуңгызга әйләндерә.

Әнә шул вакыйгадан соң яһүдиләр Гайсә галәйһис-сәләәмне үтерергә карар кыла. Хәвариләрдән Йәһудага күпмедер тәңкә акча биреп, аның аркылы Хәзрәти Гайсә торган урынны белешәләр. Ләкин Җәбраил галәйһис-сәләәм Рухуллаһны янынннан һич китмичә саклый. Аяти кәримәдә болай диелә:

وَآتَيْنَا عِيسَى ابْنَ مَرْيَمَ الْبَيِّنَاتِ وَأَيَّدْنَاهُ بِرُوحِ الْقُدُسِ

**«...Мәрьям улы Гайсәгә Без ап-ачык дәлилләр (могҗизалар) бирдек һәм Изге рух белән куәтләдек...»** («әл-Бәкара», 253).

Ниһаять, Гайсә галәйһис-сәләәм Аллаһ тарафыннан күккә ашырыла. Ул вакытта аңа утыз өч яшь була.

Яһүдиләр Хәзрәти Гайсә торган өйгә кергәч, Җәнабел-Хак Йәһуданы Гайсә галәйһис-сәләәм кыяфәтендә чыгара һәм Рухуллаһ урынына алар Йәһуданы үтерә. Аллаһ Тәгалә әйтә:

وَبِكُفْرِهِمْ وَقَوْلِهِمْ عَلَىٰ مَرْيَمَ بُهْتَانًا عَظِيمًا وَقَوْلِهِمْ إِنَّا قَتَلْنَا الْمَسِيحَ عِيسَى ابْنَ مَرْيَمَ
رَسُولَ اللَّهِ وَمَا قَتَلُوهُ وَمَا صَلَبُوهُ وَلَكِنْ شُبِّهَ لَهُمْ وَإِنَّ الَّذِينَ اخْتَلَفُوا فِيهِ لَفِي شَكٍّ
مِنْهُ مَا لَهُمْ بِهِ مِنْ عِلْمٍ إِلَّا اتِّبَاعَ الظَّنِّ وَمَا قَتَلُوهُ يَقِينًا

**«Янә аларның инкяр итүләре һәм Мәрьямгә зур яла якканнары өчен. Янә аларның: “Һичшиксез, без Аллаһның рәсүле Мәрьям улы Гайсә Мәсихне үтердек”, – дигәннәре өчен (аларга ләгънәт кылдык). Хәлбуки, алар аны үтермәделәр дә, кадакламадылар да. Ләкин алар өчен (үтергән затлары Гайсә сурәтенә) охшатылды. Һичшиксез, бу хакта фикер каршылыгына төшкәннәр – аның хакында шик эчендәләр. Аларның бу хакта фаразга иярүдән башка бернинди (ныклы) гыйлемнәре юк. Һәм алар аны, шиксез, үтермәделәр»** («ән-Ниса», 156–157).

بَلْ رَفَعَهُ اللَّهُ إِلَيْهِ وَكَانَ اللَّهُ عَزِيزًا حَكِيمًا

**«Аллаһ аны (Гайсәне) Үзе өстен кылган урынга күтәрде. Аллаһ – Бөек, Хикмәт иясе»** («ән-Ниса», 158).

Аллаһ Гайсә галәйһис-сәләәмне яһүдиләрдән саклап кала, аны үтерүләренә комачаулый. Монысы анык, пәйгамбәрне Үз катына күтәрүе дә шик уятмый. Ләкин бу гамәлнең ничек һәм кайчан чынга ашырылуы мәсьәләсендә төрле риваятьләр яшәп килә. Күпләр фикеренчә, Аллаһ Җәллә Җәләлүһү Үзенең көч-кодрәте белән Гайсә галәйһис-сәләәмне рухи күк галәмендәге шәхсән

аның өчен билгеләнгән урынга күтәреп куя. Кыямәт алдыннан аны кабат дөньяга җибәрәчәк. Ул вакытта бөтен христианнар мөселманлыкка күчәчәк һәм ислам дөньяда берданбер дин булып калачак. Аяти кәримәдә болай дип хәбәр ителә:

وَمَكَرُوا وَمَكَرَ اللَّهُ وَاللَّهُ خَيْرُ الْمَاكِرِينَ

**«Алар (яһүдиләр) хәйлә кордылар, Аллаһ та тиешлесен бирде (тозакларын бозды). Аллаһ бит – хәйләләргә каршы торуда иң өстене»** («Әли Гыймран», 54).

إِذْ قَالَ اللَّهُ يَا عِيسَىٰ إِنِّي مُتَوَفِّيكَ وَرَافِعُكَ إِلَيَّ وَمُطَهِّرُكَ مِنَ الَّذِينَ كَفَرُوا وَجَاعِلُ الَّذِينَ اتَّبَعُوكَ
فَوْقَ الَّذِينَ كَفَرُوا إِلَىٰ يَوْمِ الْقِيَامَةِ ثُمَّ إِلَيَّ مَرْجِعُكُمْ فَأَحْكُمُ بَيْنَكُمْ فِيمَا كُنْتُمْ فِيهِ تَخْتَلِفُونَ

**«Аллаһ әйтте: “И, Гайсә! Һичшиксез, Мин – сине алучымын (алар түгел), сине Үзем күтәргән урынга күтәрүчемен, сине кяферләрдән (аралап) пакь кылучымын һәм Кыямәт көненә кадәр сиңа ияргәннәрне инкяр итүчеләрдән өстен итүчемен. Соңыннан кайтуыгыз тик Миңа (булачак). Сез ихтилаф иткән нәрсәләрегез хакында арагызда Мин хөкем бирәчәкмен»** («Әли Гыймран», 55).

فَأَمَّا الَّذِينَ كَفَرُوا فَأُعَذِّبُهُمْ عَذَابًا شَدِيدًا فِي الدُّنْيَا وَالْآخِرَةِ وَمَا لَهُمْ مِنْ نَاصِرِينَ

**«Кяферләргә дөньяда да, ахирәттә дә каты газап бирәчәкмен. Аларга ярдәмчеләр һич юк!»** («Әли Гыймран», 56).

وَأَمَّا الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ فَيُوَفِّيهِمْ أُجُورَهُمْ وَاللَّهُ لَا يُحِبُّ الظَّالِمِينَ

**«Иман китергән һәм изге гамәлләр кылган кешеләргә исә (Аллаһ) әҗерләрен тулысынча бирәчәк. Аллаһ залимнәрне сөйми»** («Әли Гыймран», 57).

### Гайсә галәйһис-сәләәм күккә ашканнан соң

Гайсә галәйһис-сәләәм күккә күтәрелгәннән соң, христианнар җитмеш ике фиркагә (төркемгә) бүленә. Өчлек гакыйдәсе барлыкка килә. Христианнарның Ягъкубия агымы: «Аллаһ Гайсәгә керде. Аның тәнендә гәүдәләнде һәм аның рәвешендә күзгә күренде. Ягъни Аллаһ – Гайсә ул», – диләр.

Мондый караш һинд философиясеннән килә. Иерусалим һинд мәдәниятенең һәм Римның даими йогынтысында яши. Һинд философиясенә күрә, Аллаһ дөньяга иңә һәм бер ата-анадан туган Кришнада гәүдәләнә. Шул рәвешле Кришна яралтучыга, Аллаһка әйләнә.

Югыйсә Коръәни-Кәримдә анык әйтелә:

لَقَدْ كَفَرَ الَّذِينَ قَالُوا إِنَّ اللَّهَ هُوَ الْمَسِيحُ ابْنُ مَرْيَمَ وَقَالَ الْمَسِيحُ يَا بَنِي إِسْرَائِيلَ اعْبُدُوا اللَّهَ رَبِّي وَرَبَّكُمْ إِنَّهُ مَنْ يُشْرِكْ بِاللَّهِ فَقَدْ حَرَّمَ اللَّهُ عَلَيْهِ الْجَنَّةَ وَمَأْوَاهُ النَّارُ وَمَا لِلظَّالِمِينَ مِنْ أَنْصَارٍ

**«“Аллаһ – Мәрьям улы Мәсих ул”, – дип әйтүчеләр кяфер булдылар. Хәлбуки, Мәсих: “И, Исраил уллары! Минем дә Раббым, сезнең дә Раббыгыз булган Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Кем дә кем Аллаһка ширек кушса, Аллаһ җәннәтне аңа харам кылды. Аның сыенасы урыны – Ут. Залимнәргә ярдәмчеләр юк”, – дигән иде»** («әл-Маидә», 72).

مَا الْمَسِيحُ ابْنُ مَرْيَمَ إِلَّا رَسُولٌ قَدْ خَلَتْ مِنْ قَبْلِهِ الرُّسُلُ وَأُمُّهُ صِدِّيقَةٌ كَانَا يَأْكُلَانِ الطَّعَامَ انْظُرْ كَيْفَ نُبَيِّنُ لَهُمُ الْآيَاتِ ثُمَّ انْظُرْ أَنَّىٰ يُؤْفَكُونَ

**«Мәрьям улы Мәсих – бер пәйгамбәр генә. Аңа кадәр дә (күп кенә) пәйгамбәрләр киткән иде. Анасы да бер тугры хатын гына. Алар икесе дә азык ашыйлар иде. Безнең дәлилләрне аларга ничек итеп бәян иткәнебезне кара. Шуннан соң аларның ничек читләшкән булуларын кара»** («әл-Маидә», 75).

Бу аяти кәримәләрдә Җәнабел-Хак тулысы белән ширектән гыйбарәт тәслис (троица) гакыйдәсенең ялгышлыгын белдерә.

Гайсә галәйһис-сәләәмнең күккә ашырылуыннан соң барлыкка килгән җитмеш ике агым, карашлары нигезендә, төп өч төркемгә аерып карала ала:

1. «Гайсә безнең арадагы Аллаһ иде, хәзер китеп барды», – дип санаучылар;

2. «Гайсә Аллаһның улы иде, хәзер китеп барды», – диючеләр;

3. «Гайсә галәйһис-сәләәм – Аллаһның колы һәм рәсүле. Аллаһ Җәллә Җәләлүһү аны күккә ашыру юлы белән, аны рәхмәтен, хөрмәтен ирештерде», – дип раслаучылар.

Беренче ике төркем – көферлеккә һәм бозыклыкка батучылар, өченче төркем исә – чын иман ияләре.

Хәзрәти Гайсә күккә ашканнан соң да, яһүдиләр хәвариләрне газаплаудан туктамый. Хәвариләр барлык җәза-газапларны бик зур сабырлык белән кичерә.

Хәвариләрнең берсе булган Варнава Гайсә галәйһис-сәләәмнең соңгы көннәре турында Инҗиленең 221 һәм 222 нче бабларында мондый мәгълүмат бирә:

Рим гаскәрләре Хәзрәти Гайсәне тоту өчен өйгә кергән чакта, Җәнабел-Хак әмере белән дүрт олуг фәрештә пәйгамбәрне тәрәзәдән алып чыгып, күккә күтәреп киттеләр. Рим гаскәрләре: «Син – Гайсә!» – дип, Йәһуданы эләктереп алдылар һәм, аның ялваруларына карамастан, аркылы агачка тартып үтерделәр. Соңрак Гайсә галәйһис-сәләам әнисе Мәрьямгә һәм хәвариләренә күренде. Хәзрәти Мәрьямгә: «Әнкәм, күрәсең ки, мине асмадылар. Минем урынга аркылы агачка Йәһуданы кадаклап астылар. Шайтаннан сакланыгыз, чөнки ул, дөньяны бизәп күрсәтеп, сезне алдарга тырышачак», – диде.

Аннары Гайсә галәйһис-сәләам, иман ияләрен сакласын өчен, Җәнабел-Хакка дога кылды. Шуннан соң хәвариләренә борылды да: «Аллаһ Җәллә Җәләлүһүнең рәхмәте вә нигъмәте сезнең белән булсын!» – дип әйтте. Бу сүзләреннән соң дүрт олуг фәрештә аны кабат күккә күтәреп алдылар.

Гайсә галәйһис-сәләам күккә ашып, кырык ел узгач (б.э. 70 нче елларында) римлылар Тит (Титус) җитәкчелегендә Иерусалимне талыйлар. Яһүдиләрнең бер өлешен үтереп, бер өлешен әсирлеккә төшерәләр. Тәүратны һәм башка китапларның барысын да яндыралар. Бәйтүл-Макдисне хәрабәгә әйләндереп, Сөләйман гыйбадәтханәсен җимерәләр. Храмнан бер дивар гына торып кала. Яһүдиләр бүген «Елау дивары» (Көнбатыш стена) исеме белән билгеле шул калдык дивар каршында, шул көннәрдә булган фаҗигане искә алып, яшь түгә. Шул вакыйгада соң яһүдиләр бергә туплана алмый, түбәнсетелеп-кимсетелеп яшиләр.

Йәһуда диннән ваз кичкәч, хәвариләр аның урынына Матхиасны сайлап куя. Аннары, төрле якларга таралып, Гайсә галәйһис-сәләам динен таратуга керешәләр. Гайсә галәйһис-сәләам дине тарафдарлары күбәя башлагач, римлылар, греклар һәм мәҗүси халыклар белән берләшеп, яһүдиләр бу дингә каршы көрәшкә чыга: христиан динен кабул иткән тәүге яһүдиләрне гавам каршында арысланнарга ботарлаттыралар. Христианнар бик авыр җәзалар, иза-газаплар кичерә.

Яһүди Зунувас һәм аның ярдәмчеләре яһүдилекне кабул итмәгән Нәҗран христианнарын утлы чокырга ташлап яндыра, үзләре исә шул тереләй янган кешеләрне күзәтеп торалар. Шушы авырлыкларга карамастан, Гайсә галәйһис-сәләамнең тугры мөэминнәре иманнарыннан баш тартмый, диннәре хакына һич куркусыз үлемгә керәләр. «Әсхабе Ухдуд» дип искә алына торган бу мөэминнәр турында Коръәни-Кәримдә болай диелә:

وَالسَّمَاءِ ذَاتِ الْبُرُوجِ وَالْيَوْمِ الْمَوْعُودِ وَشَاهِدٍ وَمَشْهُودٍ قُتِلَ أَصْحَابُ الْأُخْدُودِ النَّارِ
ذَاتِ الْوَقُودِ إِذْ هُمْ عَلَيْهَا قُعُودٌ وَهُمْ عَلَىٰ مَا يَفْعَلُونَ بِالْمُؤْمِنِينَ شُهُودٌ

**«Йолдызлыклар иясе булган күк белән ант итәмен. Вәгъдә ителгән Көн белән дә. Шаһитлык кылачак һәм шаһитлык кылыначак (көн) белән**

**дә. Һәлак булсын чокыр ияләре! Ягыла торган нәрсәләргә ия булган ут (ияләре). Менә алар аның тирәсендә утыралар. Алар – мөэминнәргә кылган нәрсәгә (җәфаларга) шаһитлар»** («әл-Бүруҗ», 1–7).

Яһүдиләр мондый явызлыклар, рәхимсезлекләр белән генә чикләнеп калмый. Алар христианлыкны[170] тамырдан корыту планын кора. Болүс (Павел) исемле бер яһүди, үз уйдырмаларын да кушып, төрле китаплар яза. «Гайсә – Аллаһның улы!» – дип, ул үзен Гайсә дине тарафдары буларак күрсәтә. Ул шәраб белән дуңгызның хәләллеге, шимбә көненә бәйле тыюларны үтәүнең, ир-атларны сөннәтләүнең кирәксезлеге турында сөйли. Шул рәвешле Хәзрәти Муса шәригатендә булган әмерләргә һәм тыюларга буйсыну кирәк түгеллеген белдерә. Бәндә өчен иманның җитәрлек икәнлеген, гамәлгә ихтыяҗ юклыгын алга сөрә. Югыйсә Хәзрәти Гайсә Хәзрәти Муса шәригате белән гамәл кыла. Шулай ук Инҗилдә Хәзрәти Гайсәнеке дип тапшырылган мондый сүзләр дә бар: «Минем хакта, Муса канунын яки пәйгамбәрләр язганнарны юкка чыгарырга килгән, дип уйламагыз. Мин юкка чыгарырга дип түгел, башкарырга дип килдем» (Матфей Инҗиле, 5/17).

Шуңа күрә Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәм гомере буе яһүди храмнарында гыйбадәт кыла, сөннәтләнгән була, шәраб эчүдән, дуңгыз ите ашаудан тыела һәм боларны тыя. Павел һәм аның дуслары исә Хәзрәти Гайсә дә, Аллаһ Тәгалә дә, аларга мондый вәкаләт бирмәгән хәлдә, андый тыюларны юкка чыгарып, динне күрәләтә үзгәртеп бозалар һәм христианлыкны үз нәфесләренең теләкләренә күрә формалаштырырга тырышалар.

Павел: «Аллаһ – берәү, ә сыйфаты – өчәү», – дип белдерә. Динне ул Платон философиясе яраштырып аңлата. Платон фәлсәфәсенең нигез карашлары түбәндәгедән гыйбарәт:

1. Күзгә күренмәгән яралтучы – Алла;

2. Алланың күзгә күренә һәм танып-беленә торган ярдәмчесе – «логос» (мантыйк);

3. Күзгә күренә һәм танып-беленә торган галәм.

Павел исә христианлыкның дин нигезен болай дип кора:

1. Аллаһ;

2. Аның улы Гайсә;

3. Изге рух.

Шулай итеп христианлыкка бүгенге тәслис гакыйдәсе кереп урнаша.

Ул чордагы шартлар да мондый үзгәрешләр кертүгә кулай була, чөнки халык, диннәренә артык бирелгәнлекләре сәбәпле, яһүдилекне бер дә ошат-

170. Христианлык – христиан дине, нәсара дине.

мый. Ә бу яңа тәслис гакыйдәсен ата-бабаларыннан килгән күпаллалык диненә якынрак итеп күрәләр.

Шуннан соң христианнар икегә аерыла:

1. Болүсчеләр (Павел тарафдарлары). Аларга корольләр иярә, шуңа күрә бик тиз көчәеп китәләр. Гайсә галәйһис-сәләәм күккә ашканнан соң, үзенең христиан икәнлеген белдергән Павел, бу яңа динне, асыл иманнан ераклаштырып, өчлек фәлсәфәсенә нигезләнгән бер инану системасына әйләндерә. Соңрак бүгенге Инҗилләрнең (Яңа Гаһеднең) әһәмиятле өлешен тәшкил иткән һәм әүвәлге дүрт Инҗилгә чыганак булып торган 14 төрле китап яза. Алар исә христианнарның изге язмалары арасында дүрт Инҗил кебек үк әһәмияткә ия.

2. Варнавачылар: «Гайсә галәйһис-сәләәм – пәйгамбәр булган гап-гади кеше. Аңа һич табынырга ярамый», – ди. Шулай ук хәвари Ягъкуб җитәкчелегендәге эбионитлар да шушы төркемгә кушыла, шундый ук фикерне яклый. Үзләренә ярдәм итәрлек корольләр булмаганга күрә, Варнава тарафдарлары бик тиз көчсезләнә, азая. Җитмәстән, Павелга иярүчеләрнең дошманнарча мөнәсәбәте көннән-көн көчәя һәм варнавачылар санын киметә. Өстәвенә, 325 елда Константин тарафыннан җыелган собордагы дин әһелләре шурасы Варнава Инҗилен гамәлдән чыгара һәм ул вакыттагы бик күп Инҗилләрдән бер-берсенә якын дүрт Инҗилне генә кулланышка кабул итәләр. Болар – Лука, Иоанн (Йуһанна), Марк (Маркос) һәм Матфей (Матта) Инҗиле. Әлеге дүрт Инҗилдән кала башкалары юкка чыгарыла. Шушылардан кала башка Инҗилләр рәсми чиркәү тарафыннан ялган дип санала.

Бу карардан соң бары дүрт бозылган Инҗил генә рәсми рәвештә языла-укыла башлый. Шулай итеп, иң ышанычлы Инҗил булуына карамастан, башкалар белән бергә Варнава китабы да гамәлдән чыгарыла. Чынлыкта Варнава хәвариләрнең иң беренчеләреннән була. Гайсә галәйһис-сәләәмнән ишеткәннәрне, күргәннәрне дөрес итеп язып бара. Ләкин бу хәл яһүди Павел һәм аның иярченнәренең мәнфәгатенә туры килми, шул сәбәпле Варнаваны читкә этәрәләр. Шул дәрәҗәдә ки, Гайсә галәйһис-сәләәмнең күккә ашырылуыннан соң утыз ел узгач Кипрда шәһид киткән Варнаваны хәзерге христианнар да, Никея соборында кабул ителгән карарга нигезләнеп, хәвариләрнең берсе дип санамый. Аның урынына хәвари исемлегенә Томасны кертәләр.

Варнавадан соң Ариус (Арий) исемле бер дин әһеле Павел тарафдарлары белән көрәшкә күтәрелә, ләкин ул, чиркәүдән куылып, анафемага бирелә. Арий Мисырга китә, шунда тәүхид динне тарату белән шөгыльләнгәндә һәлак ителә.

Арийның христианлыкка карата тәнкыйтенә рәсми чиркәү бөтен тарих дәвамында христианнарны канәгатьләндерерлек җавап бирә алмый. Моңа охшаган тәнкыйть сүзләре христиан дине тарихында һәр чорда кабат-кабат

баш калкыта һәм рәсми чиркәүнең абруе һәм ул кабул иткән гакыйдә какшауга бер сәбәп була. Христиан дин әһелләре мондый тәнкыйтьләргә җавап бирү, христиан җәмгыятенең бердәмлеген тәэмин итү һәм, иң мөһиме, христиан дине нигезләрен ачыклау өчен, күп тапкыр утырышлар, соборлар уздыра һәм бу җыеннарда төрле карарлар кабул итә.

Әйтик, беренче собор 325 елда Никеяда (хәзерге Төркиядәге Изник шәһәре) уздырыла, бу соборда Гайсәнең илаһ булуы игълан ителә, 381 елгы Константинополь (Истанбул) соборында исә Изге рухның да илаһ булуы кабул ителеп, тәслис гакыйдәсе формалашу тәгәлләнә. 431 елда Эфес соборында Мәрьямнең Алла анасы итеп танылa, 451 елгы Халкидон соборында Гайсәнең табигате белән бәйле карашлар турында фикер алышалар һәм чиркәүләр арасында каршылыклар баш калкыта. 869 елда янә Константинопольдә үткәрелгән 8 нче соборда Изге рухның кемнән чыкканлыгы турында бәхәс башлана. Мондый озын-озак бәхәсләр нәтиҗәсендә 1054 елда христианлык дине католиклык (Рим) һәм ортодоксизм (Константинополь) рәвешендә ике зур мәзһәпкә аерыла. XVI гасырда схоластик һәм иректне чикләүче католиклыкка протест буларак, протестантлык агымы барлыкка килә.

Барлык христианнарны кызыксындырган, шул ук вакытта диннең нигезен тәшкил иткән иң төп принципларны һәм үзәк караш-фикерләрне соңыннан аерым кешеләрнең ачыкларга, билгеләргә маташуы ул диннең никадәр үзгәртүгә дучар ителгәнлеген һәм асылының бозылганлыгын ап-ачык күрсәтә. Өстәвенә, бу соборларда кабул ителгән карарлар кайчак бер-берсенә каршы килә. Дөньяда уен уйнаган кебек шулкадәр күп үзгәртелгән һәм һәр юлы нәрсәдер алып ташланып, яңа нәрсәләр өстәлгән башка дин таба алмассыз.

### Инҗилләрнең күп язылу сәбәбе

Үзгәртелгән христиан динендәге өчлек гакыйдәсенә күрә, Аллаһ, Аллаһның улы – Хәзрәти Мәсих (Гайсә) һәм Изге рух бар. Бу карашны яклаган бик күп руханилар, Изге рухның аларга вәхи иңдерүе турында белдереп, Инҗил язарга алынганнар. «Изге рух – Җәбраил ул» яки «кешенең йөрәгенә илһам бирә торган рухи көч ул» кебек буталчык фикерләр әйтелә. Анык аңлатма юк. Хәтта хәзерге заманда да шул рәвешле Инҗил язучылар очрый.

### Гайсә галәйһис-сәләәмнең күктән иңдерелүе

Гайсә галәйһис-сәләәм, кыямәт якынлашкач, күктән җиргә төшәчәк. Бу мәсьәләгә бәйле бик күп хәдис-шәриф бар. Коръәни-Кәримдә болай диелә:

وَإِنَّهُ لَعِلْمٌ لِلسَّاعَةِ فَلَا تَمْتَرُنَّ بِهَا وَاتَّبِعُونِ هَذَا صِرَاطٌ مُسْتَقِيمٌ

**«Һичшиксез, ул (Гайсә) – сәгатьнең (кыямәтнең кайчан кубачагы) билгесе. Аңардан һич шөбһәләнмәгез! Сез Миңа иярегез! Бу – туры юл»** («әз-Зухруф», 61).

Әлеге аятьтә Хәзрәти Гайсәнең кыямәт якынлашу турында бер билге икәнлеге белдерелеп, ахырзаманда аның кабат бу дөньяга кайтачагына ишарә ителә. Шулай ук аятьтәге «гыйлем» сүзе «ишарәт» мәгънәсендәге «галәм» рәвешендә дә укыла.

Җир йөзенә төшкәч, Гайсә галәйһис-сәләәм Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәригате белән хөкем итәчәк. Ул Мәһди галәйһис-сәләәм белән бергә булачак һәм Мәһди җирдә Дәҗҗалны юк итәчәк. Мәһди галәйһис-сәләәм Хашими нәселеннән чыгып, хәлифәтне Гайсә галәйһис-сәләәмгә тапшырачак.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай ди: *«Гомерем озынайса, Гайсә белән очрашырга теләр идем. Әгәр гомерем җитмәсә, арагыздан кем аның белән күрешә, шул Миннән сәлам әйтсен»* (Ибне Ханбәл, II, 298).

Хәзрәти Гайсәнең җир йөзенә иңдерелүе бөтен кешелек өчен бер рәхмәт булачак. Хәдис-шәрифтә болай дип әйтелә:

*«Хәзрәти Гайсә кызыл балчык төсендәге ике кием кигән рәвештә төшәр, хачны җимерер, дуңгызны үтерер, җизья салымын бетерер, кешеләрне исламга өндәр. Аллаһ аның чорында исламнан кала бөтен диннәрне юкка чыгарыр. Җир йөзенә тынычлык килер. Арысланнар дөяләр белән бергә ашап йөрер. Балалар еланнар белән уйнар»* (Карагыз: Ибне Мәҗә, «Фитән», 33/4077).

Бу мәсьәләгә караган башка бер хәдис-шәриф:

*«Җаным кодрәтле кулында булган Зүл-Җәләли белән ант итәм. Мәрьям улы Гайсә арагызга (ислам шәригате белән хөкем итәчәк) гадел хаким буларак төшәчәк, тәреләрне җимереп, дуңгызларны үтерәчәк, җизьяне (китап әһелләреннән) бетерәчәк (ягъни китап әһелләре дә мөселман булып, иудаизм һәм христианлык бетәчәк) вакыт якын. Ул чакта мал шулкадәр артыр ки, һичкем аны кабул итмәс, бу вакытта бер сәҗдә дә бөтен дөньядан һәм андагы нәрсәләрнең барысыннан хәерлерәк булыр»*.

Әлеге хәдис-шәрифне риваять кылган Әбү Һүрайра радыйаллаһу ганһе риваятенең ахырында әйтә: «Теләсәгез, менә бу аятьне укыгыз: **“Һичшиксез, әһле китаптан берсе-бер калмыйча, һәммәсе дә үлеменнән алда аңа иман итәчәк. Кыямәт көнендә исә ул аларга каршы шаһит булачак”»** («ән-Ниса», 159)» (Бохари, «Бүйу», 102, «Әнбия», 49; Мөслим, «Иман», 242).

### Гайсә галәйһис-сәләәмнең могҗизалары

Гайсә галәйһис-сәләәм Аллаһның рөхсәте белән:

1) Үлеләрне терелтә.

2) Авыруларны савыктыра.

3) Башкаларның нәрсә ашаганнарын һәм өйләрдә ни саклаганнарын белә.

4) Балчыктан кош ясап очыра.

5) Аңа күктән сыйлы табын иңә.

6) Йоклаган килеш тә, тирә-ягында сөйләнгән сүзләрне һәм кылынган эшләрне ишетә һәм белә.

7) Еракта һәм яшерен рәвештә сөйләшкәннәрне ишетә. Хәзрәти Мәрьямгә Гайсә галәйһис-сәләәм турында сөенечле хәбәр китергәндә, фәрештәләр болай дип әйтә:

وَرَسُولًا إِلَىٰ بَنِي إِسْرَائِيلَ أَنِّي قَدْ جِئْتُكُمْ بِآيَةٍ مِنْ رَبِّكُمْ أَنِّي أَخْلُقُ لَكُمْ مِنَ الطِّينِ كَهَيْئَةِ الطَّيْرِ فَأَنْفُخُ فِيهِ فَيَكُونُ طَيْرًا بِإِذْنِ اللَّهِ وَأُبْرِئُ الْأَكْمَهَ وَالْأَبْرَصَ وَأُحْيِي الْمَوْتَىٰ بِإِذْنِ اللَّهِ وَأُنَبِّئُكُمْ بِمَا تَأْكُلُونَ وَمَا تَدَّخِرُونَ فِي بُيُوتِكُمْ إِنَّ فِي ذَٰلِكَ لَآيَةً لَكُمْ إِنْ كُنْتُمْ مُؤْمِنِينَ

**«(Гайсә) Исраил улларына рәсүл буларак (килеп әйтәчәк): "Һичшиксез, мин сезгә Раббыбыздан могҗиза алып килдем. Мин сезгә балчыктан кош сурәтенә охшаган бер нәрсә ясармын, шуннан аңа өрермен һәм, Аллаһның ихтыяры белән, ул бер кошка әйләнер. Аллаһның ихтыяры белән, тумыштан дөм сукыр һәм махау авырулыны сәламәт итәрмен, үлеләрне терелтермен. Сезгә нәрсә ашаганыгызны да, нәрсә саклап тотканыгызны да хәбәр итәрмен. Һичшиксез, монда сезнең өчен, әлбәттә, билге бар; әгәр ышанган кешеләр булсагыз!"»** («Әли Гыймран», 49).

Бүтән аяти кәримәләрдә мондый хәбәр ирештерелә:

يَوْمَ يَجْمَعُ اللَّهُ الرُّسُلَ فَيَقُولُ مَاذَا أُجِبْتُمْ قَالُوا لَا عِلْمَ لَنَا إِنَّكَ أَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ

**«Аллаһ пәйгамбәрләрне туплаган көнне: "Сезгә нәрсә дип җавап кайтардылар?" – дип әйтер, алар: "Бездә бернинди белем юк. Һичшиксез, син – бөтен яшеренгәнне белүче", – дип әйтерләр»** («әл-Маидә», 109).

إِذْ قَالَ اللَّهُ يَا عِيسَى ابْنَ مَرْيَمَ اذْكُرْ نِعْمَتِي عَلَيْكَ وَعَلَىٰ وَالِدَتِكَ إِذْ أَيَّدْتُكَ بِرُوحِ الْقُدُسِ تُكَلِّمُ النَّاسَ فِي الْمَهْدِ وَكَهْلًا وَإِذْ عَلَّمْتُكَ الْكِتَابَ وَالْحِكْمَةَ وَالتَّوْرَاةَ وَالْإِنْجِيلَ وَإِذْ تَخْلُقُ مِنَ الطِّينِ كَهَيْئَةِ الطَّيْرِ بِإِذْنِي فَتَنْفُخُ فِيهَا فَتَكُونُ طَيْرًا بِإِذْنِي وَتُبْرِئُ الْأَكْمَهَ وَالْأَبْرَصَ بِإِذْنِي وَإِذْ تُخْرِجُ الْمَوْتَىٰ بِإِذْنِي وَإِذْ كَفَفْتُ بَنِي إِسْرَائِيلَ عَنْكَ إِذْ جِئْتَهُمْ بِالْبَيِّنَاتِ فَقَالَ الَّذِينَ كَفَرُوا مِنْهُمْ إِنْ هَٰذَا إِلَّا سِحْرٌ مُبِينٌ

**«Аллаһ әйтер: “И, Мәрьям улы Гайсә! Минем сиңа һәм анаңа булган нигъмәтемне хәтерлә. Сине мөкатдәс Рух (Җәбраил) белән куәтләндердек, һәм (шуның аркасында) син бишектә дә, үсеп җиткәч тә, кешеләр белән сөйләшкән идең. Сиңа китапны (уку-язуны) хикмәтне, Тәүратны һәм Инҗилне өйрәткән идем. Син, Минем рөхсәтем белән, балчыктан кош шәкеленә охшаган бернәрсә ясадың, шуннан аңа өрдең һәм ул, Минем рөхсәтем белән, бер кошка әверелде. (Тумыштан) сукырны һәм махау авырулыны да Минем рөхсәтем белән савыктырдың. Син, Минем рөхсәтем белән, үлеләрне (тормышка) чыгардың. Аларга син ап-ачык дәлилләр (могҗизалар) китергәч, алар арасыннан көферлек кылганнар: “Бу – ап-ачык бер сихер генә”, – дигән чакта, Мин Исраил улларын синнән тотып калдым (сине үтерүдән алып калдым)»** («әл-Маидә», 110).

# БҮГЕНГЕ ХРИСТИАНЛЫК

Әүвәлге бүлектә әйтеп узганыбызча, христианлык Гайсә галәйһис-сәләәмнән соң кешеләр тарафыннан бик күп тыкшынуларга, бәндәчел йогынтыга дучар була. Шуңа күрә Коръәни-Кәримдә әһле китап турында телгә алганда, «кемнәр диннәрен бүлгәләделәр» («әр-Рум», 32) дигән гыйбарә кулланылган. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдис-шәрифтә болай ди: *«...Мәсихнең өммәте аның сөннәте һәм һидәятендә ике йөз ел калды (аннары диннәрен бозып, юнәлешләрен үзгәрттеләр)»* (Хәйсәми, «Мәҗмагуз-Зәваид», VIII. 207).

Хактан да, христианлык үз руханилары тарафыннан бозылган һәм хәзерге көнгә тәүге рәвешендәге тәүхид гакыйдәсеннән тулысынча үзгәртелгән хәлдә килеп җиткән. Әнә шул бозу-үзгәртүләр сәбәпле, башка илаһи диннәр кебек, христианлыкның да хөкемнәре һәм аларны гамәлдә куллануга рөхсәт юкка чыгарыла. Аллаһ каршында соңгы һәм хак дин булып, ислам җибәрелә. Җәнабел-Хак:

إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللّٰهِ الْإِسْلَامُ

**«Һичшиксез, Аллаһ хозурында дин – ислам...»** – дип анык белдерә («Әли Гыймран», 19).

Җәнабел-Хакның мондый хөкеменә карамастан, яһүдиләр дә, христианнар да, ислам һәм аның олуг пәйгамбәре үзләре арасыннан чыгачак дип ышанганга күрә, бу динне кабул итә алмый. Һәр ике дин вәкилләре, китапларындагы хакыйкатькә карап, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм иңдерелгәнче (пәйгамбәр буларак җибәрелгәнче), Аны зарыгып көтүләренә карамастан, пәйгамбәрлек килгәч, мөнәсәбәтләре үзгәрә. Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәм яңа диннең үзләре арасыннан чыкмаганлыгын күргәч, көнчелекләре кузгала һәм алар иман китерүдән баш тарта.

Җәнабел-Хак әйтә:

وَمَا اخْتَلَفَ الَّذِينَ أُوتُوا الْكِتَابَ إِلَّا مِنْ بَعْدِ مَا جَاءَهُمُ الْعِلْمُ بَغْيًا
بَيْنَهُمْ وَمَنْ يَكْفُرْ بِآيَاتِ اللّٰهِ فَإِنَّ اللّٰهَ سَرِيعُ الْحِسَابِ

**«...Китап бирелгәннәр, үзләренә гыйлем килгәннән соң, араларында көнләшү сәбәпле, үзара ихтилаф иттеләр. Кем дә кем Аллаһның аятьләрен инкяр итә, һичшиксез, (шуны белергә тиеш:) Аллаһ – хисапны бик тиз тотучы»** («Әли Гыймран», 19).

Әһле китап көнчелеккә батып, төрле агымнарга бүленеп кенә калмыйча, китапларында ахырзаман дине ислам һәм аның хак пәйгамбәре Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында хәбәр иткән өлешләрне дә үзгәртәләр, чөнки бу бүлекләрне укучы бер төркем зирәк зиһенле христианнар яки яһүдиләр, хакыйкатьне төшенеп, шундук мөселманлык кабул итә. Әйтик, яһүди галимнәреннән Габдуллаһ ибне Сәлам һәм башка бик күпләр, христианнардан Сәлман Фариси, хәтта корольләрдән Эфиопия патшасы Нәҗаши кебек күп кенә югары даирә шәхесләре дә мөселманлыкны шул нигездә ихлас кабул кыла. Аяти кәримәдә әйтелә:

وَإِنَّ مِنْ أَهْلِ الْكِتَابِ لَمَنْ يُؤْمِنُ بِاللَّهِ وَمَا أُنْزِلَ إِلَيْكُمْ وَمَا أُنْزِلَ إِلَيْهِمْ

**«Һичшиксез, әһле китап арасында шундыйлары бар ки, Аллаһка карата түбәнчелекле буларак Аллаһка да, сезгә иңдерелгәнгә дә, үзләренә иңдерелгәнгә дә иман итәләр...»** («Әли Гыймран», 199).

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дөньяга килүе турында ишетеп, Аның сыйфатларын белешкән Византия императоры Ираклий дә, дулкынланып, Хәзрәти Пәйгамбәрнең бәхетле илчесенә: «Ул шәхес бик якын арада хәтта шушы аякларым басып торган җирләргә дә хаким булачак. Асылда, мин бу пәйгамбәрнең барлыкка киләчәген белә идем, ләкин Аның сездән булачагын дип күз алдына китермәдем. Аның каршына бара алачагымны белсәм, үзе белән очрашу өчен бөтен авырлыкларга түзәр идем. Янымда булса, аякларын юар идем», – дигән (Бохари, «Бәдгуль-Вахи», 6).

Әнә шундый һәм охшаш вакыйгаларга шаһит булган, ләкин күңелләре, теләк-ихтыярлары сукыр калган христианнар һәм яһүдиләр, вакытлар узу белән, барлык диндәшләренең мөселманга әйләнүеннән курка, борчыла башлый. Бу хәлгә бер чара сыйфатында үз китапларында урын алган, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм Ул алып килгән соңгы дин турында сөенечле хәбәрне ирештергән текстларны үзгәртәләр. Аларның бу гамәле нинди куркыныч язмышка китергәнлеге турында Җәнабел-Хак анык белдерә:

إِنَّ الَّذِينَ يَكْتُمُونَ مَا أَنْزَلَ اللَّهُ مِنَ الْكِتَابِ وَيَشْتَرُونَ بِهِ ثَمَنًا قَلِيلًا أُولَئِكَ مَا يَأْكُلُونَ
فِي بُطُونِهِمْ إِلَّا النَّارَ وَلَا يُكَلِّمُهُمُ اللَّهُ يَوْمَ الْقِيَامَةِ وَلَا يُزَكِّيهِمْ وَلَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ

**«Һичшиксез, Аллаһ иңдергән китабын (андагы ахырзаман Пәйгамбәренең сыйфатларын) яшергән һәм аны арзан бәягә алыштырганнар – әнә алар карыннарына фәкать ут кына тутыралар. Кыямәт көнендә Аллаһ аларга сүз әйтмәячәк һәм аларны пакьләмәячәк. Алар өчен тилмерткеч бер газап (бар)»** («әл-Бәкара», 174).

بِئْسَمَا اشْتَرَوْا بِهِ أَنْفُسَهُمْ أَنْ يَكْفُرُوا بِمَا أَنْزَلَ اللّٰهُ بَغْيًا أَنْ يُنَزِّلَ اللّٰهُ مِنْ فَضْلِهِ عَلَىٰ مَنْ يَشَاءُ مِنْ عِبَادِهِ فَبَاءُوا بِغَضَبٍ عَلَىٰ غَضَبٍ وَلِلْكَافِرِينَ عَذَابٌ مُهِينٌ

**«Аллаһның фазылын колларыннан теләгәненә (пәйгамбәрлек) индергәненнән көнләшкәннәре сәбәпле, Аллаһ индергәнне (Коръәни-Кәримне) инкяр итеп, җаннарын сату хисабына алган нәрсәләре яман! Алар ачу өстенә ачуга дучар булдылар. Кяферләргә мәсхәрәле газап булачак»** («әл-Бәкара», 90).

Аяти кәримәдә хәбәр ителгәнчә, хак юлдан барырга теләмичә, исламның бәхет байрагы астына керүдән баш тарткан әһле китап, үз теләк-ниятләренә күрә формалаштырылган ялган китапларына ияреп, дөнья һәм ахирәт тормышларын җимерәләр, чөнки бөтен илаһи китапларны җибәргән Аллаһ Җәллә Җәләлүһү, иң ахырдан җибәрелгән ислам юлына басмыйча, кире кагылган диннәргә ияручеләрнең ялган белән тулы иманнарын кабул итмәячәген болай дип белдереп куя:

وَمَنْ يَبْتَغِ غَيْرَ الْإِسْلَامِ دِينًا فَلَنْ يُقْبَلَ مِنْهُ وَهُوَ فِي الْآخِرَةِ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«Кем дә кем исламнан башка дин эзләсә, аңардан (андый дин) кабул ителмәячәк. ахирәттә ул зарар күрүчеләрдән булыр»** («Әли Гыймран», 85).

Хактан да, бүген исламнан кала барлык диннәрдәге һәм христианлыктагы иман белән гыйбадәт нигезләренә күз салсак, аларның Җәнабел-Хак кушканнарга, хәтта кеше мантыйгына каршы килүен күрербез. Әйтик, христианнарга күрә, һәр кеше гөнаһлы булып туа, чөнки Адәм галәйһис-сәләәм, Аллаһның кушканын үтәмәгән һәм җәннәттән куылган. Хәзер бу гөнаһ бөтен кешелектә, буыннан-буынга күчеп, дәвам итә. Гайсә галәйһис-сәләәм дөньяга кешеләрне «мәңгелек гөнаһ»тан коткару өчен килгән. Кешеләрне шул гөнаһтан коткарыр өчен, Аллаһ Җәллә Җәләлүһү үз улын (Гайсәне) хачка асып куйдырта.

Югыйсә Аллаһ Тәгалә, кешеләрнең гаеп эшләре өчен җәзаны башка берәүгә үтәттерү кебек мөнәсәбәтләр формасын бер генә илаһи китабында да телгә алмый, чөнки башка бәндәнең гөнаһы өчен гөнаһсызны корбан итү бары тик золым гына була.

Икенче яктан караганда, кешеләрнең гөнаһлы булып тууына ышану да Җәнабел-Хакка золым кылучы сыйфатын тагу дигән сүз. Бу мәсьәләнең асылын Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең түбәндәге хәдисе шулкадәр күркәм ачыклый:

**«Һәр бала фитри (ислам) белән (пакь һәм гөнаһсыз булып, тәүхиди иманга омтылышлы рәвештә) туар!..»** (Мөслим, «Кадәр», 22).

Аллаһ Тәгалә әйтә:

فَأَقِمْ وَجْهَكَ لِلدِّينِ حَنِيفًا فِطْرَتَ اللَّهِ الَّتِي فَطَرَ النَّاسَ عَلَيْهَا لَا تَبْدِيلَ لِخَلْقِ اللَّهِ ذَلِكَ الدِّينُ الْقَيِّمُ وَلَكِنَّ أَكْثَرَ النَّاسِ لَا يَعْلَمُونَ

**«(И, Рәсүлем!) Син, бер хәниф буларак, йөзеңне дингә юнәлдер. Аллаһның фитрәтенә (юнәлт), Ул бөтен кешеләрне аның белән яралтты. Аллаһның яралтуына бернинди үзгәртү булмас. Туры дин менә бу, ләкин кешеләрнең күбесе белми»** («әр-Рум», 30).

Христианлыкка кереп урнашкан ялган гакыйдәләрнең берсе «чукындыру» гамәленнән гыйбарәт. Христианнарның ата-угыл һәм Изге рух хакына чукындырылуы чиркәүнең бер таләбе санала. Чиркәү кеше йөзенә су сибеп яки тәнне суга чумдырып, чукындыру йоласын башкара. Моны христианга әйләнүнең бер игъланы, билгесе дип кабул итәләр. Шулай ук христианнар тумыштан гөнаһның чукындыру йоласы аша гафу ителүенә дә ышаналар. Шуңа күрә дә христианнар чукындыру процедурасын узмыйча үлгәннәрне гөнаһлы хәлдә вафат булган дип саныйлар.

Христианнарга күрә, дөнья – газап мәйданы ул. Анда шатлык-куанычка һәм ләззәтләргә урын юк. Кешеләр газап чигү, интегү өчен яратылган. Ләкин үзләре шулай сөйләп йөреп, нәфес баткагында төрле ләззәтләргә бирелеп, кәеф-сафа корып яшәгән христианнарның тормыш принциплары белән асыл яшәешләре һич ярашмый.

Сынау мәйданы булган бу дөньяда мәңгелек бәхеткә ирештерәчәк тормыш рәвешенең гел каршылыклардан торуы мөмкин түгел. Без шуны белергә-аңларга тиешбез: Аллаһ Тәгалә колларын төрлечә сыный. Шул сәбәпле бәндә кайчак фәкыйрьлек, кайчак муллык, кайчак кыенлык, кайчак куанычлы мизгелләр кичерер.

Шулай ук христианнар фикеренчә, кешеләр Аллаһ белән турыдан-туры элемтә кора алмас. Бәндәләр исеменнән руханилар Аллаһка ялвара, мөрәҗәгать итә ала. Аларның гөнаһларын да руханилар гафу итәргә сәләтле. Ягъни руханилар Аллаһ белән кол арасында бер арадашчы, корал вазифасын үти. Шуңа күрә дә руханиларга үз гөнаһларың турында сөйләп бирү христианлыкта бер гыйбадәт рәвешенә әйләнгән. Чиркәү гөнаһлар турында сөйләргә куша, ә руханилар исә акча бәрабәренә, гөнаһлы бәндәнең акчасы булмаса, чиркәүдә хезмәт иттерү хакына гөнаһны ярлыкарга сәләтле санала. Христианнар моны асылы үзгәртелгән, бозылган Инҗилнең түбәндәге җөмләләренә таянып аңлата:

«Гайсә аларга тагын: "Сезгә иминлек булсын! Атам мине җибәргән кебек, мин дә сезне җибәрәм", – дип әйтте. Моны әйткәч, Ул сулышын аларга өреп: "Изге Рухны кабул итегез. Кемнең гөнаһларын кичерсәгез, шуныкы кичереләр; кемнекен кичермәсәгез, аныкы кичерелмәс, – диде» (Иоанн Инҗиле, 20/21–23).

Бу ысул, мондый принцип кешегә һидәят юлын күрсәтүдән бигрәк, руханиларга үзенә күрә илаһилык сыйфаты тагу һәм башка бәндәләргә ничек тә булса гафу ителер әле, дигән сылтау белән гөнаһ эшләргә рөхсәт бирү дигән сүз.

Үз гөнаһларын да гафу итәргә мөмкинлеге булмаган руханилар башкаларның гөнаһларын ярлыкый аламы? Үзе гөнаһ эшләүдән котыла, арына алмаган бәндә, үзе кебек үк бер бәндәнең гөнаһын ничек ярлыкый алыр соң? Мондый сәләт хәтта нәбиләргә, рәсүлләргә, шул исәптән үлүл-газыйм пәйгамбәрләргә дә бирелмәгән. Пәйгамбәрләрнең гомере, һичбер гөнаһ кылмаган килеш тә, тәүбә-истигъфар белән узган, ә илаһи мәгъфирәтнең, руханилар тарафыннан ярлыкануга бәйле дип күзаллау никадәр зур ялгышлык, адашу булып тора!

Әһле китапның, илаһи хакыйкатькә каршы килеп, акча яки чиркәүдә хезмәт иттерү бәрабәренә гөнаһларны ярлыкау вәкаләтенә ия булуы турында ялгыш фикерләре, адашуы сәбәпле, Җәнабел-Хак кисәтеп куя:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِنَّ كَثِيرًا مِنَ الْأَحْبَارِ وَالرُّهْبَانِ لَيَأْكُلُونَ
أَمْوَالَ النَّاسِ بِالْبَاطِلِ وَيَصُدُّونَ عَنْ سَبِيلِ اللَّهِ

**«И, иман китерүчеләр! (Белегез) һичшиксез, руханиларның һәм монахларның күбесе кешеләрнең малларын бозык белән ашыйлар һәм (аларны) Аллаһның юлыннан яздыралар...»** («әт-Тәүбә», 34).

Шуңа карамастан, христианнар монахларына сукырларча иярә. Христианлыкның изге китабы пәйгамбәрләргә яла яккан, аларга әллә нинди гөнаһлар таккан хәлдә, һичбер пәйгамбәр сыйфаты булмаган «папа» пакь һәм гөнаһсыз зат дип кабул ителә. Ул кылган һәр эш дөрес дип санала.

Шунысы игътибарга лаек: Аллаһның әмерләрен үтәргә өндәгән, Хак Тәгалә сайлап алган пәйгамбәрләрнең илаһи чакырулары нәфесләренә хуш килмәгәнгә күрә, аларга зина кылу, хәмер эчү, ялган сөйләү, күз буу, потка табыну һ.б. шакшы сыйфатларны тагып, яла ягып, пәйгамбәрлек шәхесен кимсеткән[171] христианнар үзләре сайлап куйган бер кеше – папага чиктән тыш дәрәҗәдә югары сыйфатлар биреп, аны искиткеч бөек зат итеп күтәрәләр.[172] Коръәни-Кәримдә болай диелә:

اتَّخَذُوا أَحْبَارَهُمْ وَرُهْبَانَهُمْ أَرْبَابًا مِنْ دُونِ اللَّهِ وَالْمَسِيحَ ابْنَ مَرْيَمَ
وَمَا أُمِرُوا إِلَّا لِيَعْبُدُوا إِلَهًا وَاحِدًا لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ سُبْحَانَهُ عَمَّا يُشْرِكُونَ

171. Христианнарның изге китапларында пәйгамбәрләр белән бәйле хаксыз өстәмәләр, уйдырмаларны белү өчен, карагыз: Дөньяның яратылышы, 12/11–13, 19/30–38, 20/1–7, 30/32–4, 2 Патшалар китабы, 11 нче баб; 1 Патшалар китабы, 11/1–13.

172. Хәзерге вакытта христианнарның протестантлык тарафдарлары папаның һичкайчан хаталанмау сәләтенә ия булуын һәм гөнаһ ярлыкау вәкаләтен танымый.

**«Алар (яһүдиләр һәм христианнар) Аллаһны калдырып, руханиларын һәм монахларны, янә Мәрьям улы Мәсихне раббы иттеләр. Югыйсә, аларга бит бер илаһка гына гыйбадәт кылырга әмер ителгән иде, Аннан башка илаһ юк. Ул – аларның ширек кушкан нәрсәләреннән пакь (ерак)»** («әт-Тәүбә», 31).

Аятьтә белдерелгән хакыйкатьнең башка бер чагылышы буларак, христианнар кеше шәхесе хакында да хаталы фикер йөртә. Алар кешенең җаны һәм тәне бер-берсенә бәйләнмәгән нәрсәләр дип саный. Җанны бары руханилар гына чистарта, тән исә күпчелек очракта гөнаһлы һәм пычрак нәрсә дип кабул ителә. Югыйсә, «зүбдәи галәм» (дөньяның асылы) итеп яралтылган һәм «әшрәфи махлүкат» (мәхлукларның иң хөрмәтлесе) булган кеше турында мондый аңлатмалар һич дөрес түгел. Коръәни-Кәрим моңа бәйле хакыйкатьне болай бәян итә:

لَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنْسَانَ فِي أَحْسَنِ تَقْوِيمٍ

**«Без кешене иң күркәм сурәттә (әхсәни тәквим) яралттык»** («әт-Тин», 4).

Шәех Галиб бу хакыйкатьне бик күркәм сурәтләп биргән:

«Күңел күзе белән кара әле үзеңә.

Яралтылганнарның асылы син.

Галәмнең күз карасы булган кеше бит син!..»

Чөнки шулкадәр камил, күркәм итеп яралтылган кеше илаһи кодрәтнең мең дә бер бизәге белән ясалган бу галәмдә илаһи сәнгатьнең иң югары ноктасын тәшкил итә.

Ләкин бу бөек дәрәҗәгә лаек иман һәм гыйбадәтле тормыш алып бармаучылар яратылышта салынган югары сыйфатларны югалта. Нәтиҗәдә, Җәнабел-Хакның «әсфәли сафилин» (түбәннәрнең иң түбәне) гыйбарәсе белән тасвирланган хәлгә төшеп, илаһи әманәтне саклый алмаган булырлар. Югыйсә, һәр бәндә әүвәлдә:

وَلَقَدْ كَرَّمْنَا بَنِي آدَمَ

**«Без Адәм улларын шәрәфле (хөрмәт иясе) кылдык...»** («әл-Исра», 70) аятендәге хакыйкатькә ярашлы рәвештә дөньяга килә.

Христианнар, Инҗилләрдән төрле дәлилләр китереп, христианлыкның сөю һәм тынычлык дине икәнлеген алга сөрә. Ләкин бозылган, үзгәртелгән Инҗилләрдә моны кире каккан юллар да бар: Мәсәлән, Лука Инҗилендә Хәзрәти Гайсәдән мондый әмер тапшырыла: «Ә инде үзләре өстеннән патшалык итүемне теләмәгән дошманнарымны монда китерегез һәм күз алдымда үтерегез!» (Лука Инҗиле, 19/27).

Павелның хатларында болай диелә: «Барлык дошманнарын үз аягы астына салганчы, Мәсих патшалык итәргә тиеш бит!» (Паулдан көринтлеләргә беренче хат, 15/25).

Башка бер урында Хәзрәти Гайсәнең мондый сүзләре җиткерелә: «Мине җиргә тынычлык китерер өчен килде, дип уйламагыз. Мин тынычлык китерергә дип килмәдем, әмма кылыч алып килдем. Мин угыл белән атаны, кыз белән ананы, килен белән каенананы аерырга дип килдем!» (Матфей Инҗиле, 10/34–35).

Шулай ук христианнар кабул иткән Иске Гаһедтә болай диелә: «Аллагыз сезгә биләмә итеп бирәсе җирдәге халыкларның шәһәрләрендә исә бер җан иясен дә исән калдырмагыз. Аллагыз сезгә кушканча, бу халыкларны тәмам юк итегез» (Канун, 20/16–17).

«Хәзер син бар да амалыкыйлар җирен тар-мар китер, андагы бар нәрсәне тәмам кырып бетер, берсен-бер аяма: ир-атын вә хатын-кызын да, бала-чагасын вә күкрәк сабыен да, шулай ук үгез вә сарыкларын, дөя вә ишәкләрен дә үтереп ташла!» (1 Патшалар китабы,15/3).

Күренгәнчә, христианлыкның бозылган изге китабында мәхәббәт һәм тынычлыкка өндәүне күләгәдә калдырырлык дәрәҗәдәге явызлык һәм золымга чакырган җөмләләр дә бар.

Исламда сугышның нинди булырга тиешлеге исә Коръәни-Кәримдә анык аңлатыла:

وَقَاتِلُوا فِي سَبِيلِ اللّٰهِ الَّذِينَ يُقَاتِلُونَكُمْ وَلَا تَعْتَدُوا إِنَّ اللّٰهَ لَا يُحِبُّ الْمُعْتَدِينَ

**«Сезгә каршы сугышкан кешеләр белән Аллаһ юлында сугышыгыз, әмма чиктән ашмагыз, чөнки, һичшиксез, Аллаһ чиктән ашканнарны сөйми!»** («әл-Бәкара», 190).

Исламда сугыш Аллаһның диненә өндәү өчен алып барыла. Дошманнар белән сугышырга кушкан аятьләр бары тик сугыш игълан ителгән кешеләргә, үзләре сугыш ачканнарга карата гына юнәлдерелгән. Сугышмаган хатын-кызлар, балалар, өлкән яшьтәгеләр һәм авыруларга кагылырга ярамый, хәтта хайваннарны да үтерү тыела, яшь агачлар киселми, игеннәргә зыян салынмый[173].

Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәм, башка пәйгамбәрләр шикелле, Аллаһ хәрәм кылганны хәрәм, хәләл дигәнне хәләл дип белдергән һәм өммәтенә дә шуларны кушкан пәйгамбәр була. Хәрәмнәрдән кала, диннең асылына туры килмәгән, ләкин тышкы яктан дөрес кебек күренгән гамәлләрне, ягъни бидгатьләрне аның кире какканлыгы хак булган хәлдә, бүгенге христианлыкта

173. . Карагыз: Мөслим, «Җиһад», 3; Әбу Давыт, «Җиһад», 82.

гөнаһлар гыйбадәт хәленә китерелгән. Шуларның берсе «Өлеш алу» (Ишаи Раббани) гадәтеннән гыйбарәт.

Өлеш алу, Гайсә галәйһис-сәләәмнең соңгы төндә ашаган ризыгын символаштырып, икмәкне сындырып алып, шуңа шәраб салып ашау дигән сүз. Гүя монда икмәк Хәзрәти Гайсәнең итен, шәраб исә аның канын белдерә. Шуларны ашап, христианнар Хәзрәти Гайсә белән берләшүләренә ышана. Евхаристия исеме белән дә билгеле бу йола чукындырудан соң икенче иң мөһим гыйбадәт гамәле санала. Бу йола барлык христианнар тарафыннан үтәлә.

Элегрәк вакытларда бу йола елга бер тапкыр башкарылса, соңрак һәр атна үтәлә башлый һәм христиан диненең бер гакыйдәсенә әверелә. Мондый гыйбадәт ярдәмендә үзенә күрә югары рухияткә ирешү белән бәйле ышану илаһи тәүхид берничек тә хупламаган ширек төре булып тора.

Христианлыкта гыйбадәт күбесенчә дога һәм Тәңре исеменә атап укыла торган берничә төрле илаһи җырлардан гыйбарәт. Икмәк-шәраб йоласы яки гыйбадәтеннән кала, исламдагы кебек намаз, ураза, хаҗ һәм башка шуларга охшаш гыйбадәтләр юк. Христианлыкта ураза бары үзенә күрә диетадан гына тора. Нәфес теләгән кайбер ризыклар һәм эчемлекләр ураза вакытында тыела, ләкин җиңелчә иртәнге яки кичке ашны ашарга ярый.

Аллаһ Тәгалә христианнарның диннәренә өстәгән мондый йола-ышануларның ялган икәнлеген һәм болар хакында әмер килмәгәнен хәбәр итеп, болай дип белдерә:

وَمَا تَفَرَّقَ الَّذِينَ أُوتُوا الْكِتَابَ إِلَّا مِنْ بَعْدِ مَا جَاءَتْهُمُ الْبَيِّنَةُوَمَا أُمِرُوا إِلَّا لِيَعْبُدُوا اللَّهَ
مُخْلِصِينَ لَهُ الدِّينَ حُنَفَاءَ وَيُقِيمُوا الصَّلَاةَ وَيُؤْتُوا الزَّكَاةَ وَذَلِكَ دِينُ الْقَيِّمَةِ

**«Китап бирелгән кешеләр үзләренә ачык дәлил (Хәзрәти Пәйгамбәр һәм ислам) килгәннән соң гына бүленделәр. Аларга бит диндә Аңа гына ихлас булып, хәниф кешеләр буларак Аллаһка гына гыйбадәт кылырга, намаз укырга һәм зәкят бирергә әмер ителгән иде. Хак дин – менә шушы!»** («әл-Бәййинә», 4–5).

Югарыда сөйләгәннәр белән бергә, христианнардагы иң зур тайпылыш – диннәренә соңыннан өстәлгән «тәслис гакыйдәсе» (өчлек кагыйдәсе). Исламга өндәү өчен христиан динендәге патшаларга җибәргән хатларында Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм дә бу мәсьәләгә туктала. Византия императоры Ираклийгә юллаган хаты менә мондый:

Аллаһның колы һәм Рәсүле Мөхәммәдтән римлыларның башлыгы Ираклийгә! Һидәяткә иярүчеләргә сәлам булсын!

Мин сине исламга чакырам. Исламга кер дә, иминлеккә ireш һәм Аллаһ та сиңа әҗерен ике кат күбрәк бирсен! Әгәр кабул итмәсәң, (сиңа ияргән) игенчеләрнең гонаһы муеныңа асылыр.

**«Әйт: “И, әһле китап! безнең белән сезнең арада уртак булган һәм Аллаһтан башкага гыйбадәт кылмыйбыз, Аңа һичнәрсәне тиңдәш итмибез, Аллаһны ташлап, берәүләребез икенчеләребезне раббылар итеп санамыйбыз дигән сүзгә килик”. Әгәр алар йөз чөерсәләр, әйтегез: “Шаһит булыгыз, без – мөселманнарбыз!”»** («Әли Гыймран», 64) (Бохари, «Бәдгуль-Вахи», 5, 6; Мөслим, «Җиһад», 74).

### Тәслискә (Өч тәңрегә) ышану

Тәслис – христианнарның «Ата, угыл һәм Изге Рух» өчлегеннән гыйбарәт илаһи ышануларын белдергән төшенчә. Чынлыкта христианлык, гомумән алганда, бер Тәңрегә ышанган диннәр арасында искә алына. Христианнар нигез итеп алган «Иске Гаһед»тә тәүхид дин мәсьәләсенә бик җентекле игътибар бирелә. Христианнарның үзәге – Иерусалимдә, аны ике яктан кысрыклаган һинд һәм грек мәдәнияте тәэсирендә, христианлык тәүхидкә каршы килә торган рәвеш ала.

Тәслис христиан диненә шактый соң килеп керә. 325 елда җыелган Никея конференциясендә әле тәүхид кагыйдәсе булмый. Анда бары ата белән угылның, Тәңре булганлыктан, бер үк җәүһәрдән (асылдан) гыйбарәт икәнлекләре әйтелә. Соңрак, 381 елгы Константинополь конференциясендә исә Тәңрелеккә Изге Рухны да өстәп, тәслис кагыйдәсен кабул итәләр һәм христианнарның «өч укнум»га, ягъни өч элементлы бер илаһка табынырга тиешлеген билгеләр.

Бүгенге протестлар, ризасызлыклар каршында тәслис төшенчәсен: «Тәңре бердәнбер ул, аңарда –көч-куәт; Гайсә исә аның улы гына; Изге Рух исә – Тәңренең көче ул» кебек сүзләрне аңлатырга маташу ширек гамәлне тәүхидкә якынайтмый. Өстәвенә, һәртөрле кимчелекләрдән һәм бәндәчел сыйфатлардан азат Аллаһка бала табу куркыныч газапка дучар итәчәк бик зур ширектән кала башка нәрсә була алмый. Бу мәсьәләдә Җәнабел-Хак болай ди:

قُلْ يَا أَهْلَ الْكِتَابِ تَعَالَوْا إِلَىٰ كَلِمَةٍ سَوَاءٍ بَيْنَنَا وَبَيْنَكُمْ أَلَّا نَعْبُدَ إِلَّا اللَّهَ وَلَا نُشْرِكَ بِهِ
شَيْئًا وَلَا يَتَّخِذَ بَعْضُنَا بَعْضًا أَرْبَابًا مِنْ دُونِ اللَّهِ فَإِنْ تَوَلَّوْا فَقُولُوا اشْهَدُوا بِأَنَّا مُسْلِمُونَ

**«(Ул һәртөрле хатадан пакь, бәндәчел сыйфатлардан азат бөек зат булган килеш) “Аллаһның баласы бар!” – диделәр. Ул пакь! Күкләрдә һәм җирдә булган һәрбер нәрсә – Аныкы. Һәммәсе дә Аңа итагать итәләр»** («әл-Бәкара», 116).

قَالُوا اتَّخَذَ اللّٰهُ وَلَدًا سُبْحَانَهُ هُوَ الْغَنِيُّ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ
إِنْ عِنْدَكُمْ مِنْ سُلْطَانٍ بِهٰذَا أَتَقُولُونَ عَلَى اللّٰهِ مَا لَا تَعْلَمُونَ

**«(Әйе, Ул һәртөрле хатадан пакь, бәндәчел сыйфатлардан азат бөек зат булган килеш) алар: "Аллаһ бер бала алды", – диделәр. Ул – пакь! Ул – Бай (балага ихтыяҗы юк). Күкләрдә булганнар һәм җирдәгеләр – Аныкы гына. Сезнең моңа каршы бернинди дәлилегез юк. Әллә сез Аллаһка белмәгән нәрсә белән яла ягасызмы?»** («Йунус», 68).

قُلْ إِنَّ الَّذِينَ يَفْتَرُونَ عَلَى اللّٰهِ الْكَذِبَ لَا يُفْلِحُونَ

**«(И, Рәсүлем!) Әйт: "Аллаһка яла ягучылар, һичшиксез, уңышка ирешмәячәкләр"»** («Йунус», 69).

مَتَاعٌ فِي الدُّنْيَا ثُمَّ إِلَيْنَا مَرْجِعُهُمْ ثُمَّ نُذِيقُهُمُ الْعَذَابَ الشَّدِيدَ بِمَا كَانُوا يَكْفُرُونَ

**«Дөньяда бер файдалану (күрерләр). Шуннан соң кайтулары – Безгә. Шуннан соң, инкяр иткәннәре сәбәпле, Без аларга бик каты газап татытачакбыз»** («Йунус», 70).

مَا اتَّخَذَ اللّٰهُ مِنْ وَلَدٍ وَمَا كَانَ مَعَهُ مِنْ إِلَهٍ إِذًا لَذَهَبَ كُلُّ إِلَهٍ بِمَا
خَلَقَ وَلَعَلَا بَعْضُهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ سُبْحَانَ اللّٰهِ عَمَّا يَصِفُونَ

**«Аллаһ бернинди бала да алмады. Аның белән берлектә һичбер илаһ та юк. (Аның белән башка илаһлар булган очракта) һәрбер илаһ үзе бар иткән нәрсәләр белән китерер иде һәм, һичшиксез, аларның берәүләре икенчеләреннән өстен чыгар иде. Аллаһ алар (мөшрикләр) сыйфатлаган нәрсәләрдән пакь»** («әл-Мүэминүн», 91).

Баштагы мәлдә саф, чиста тәүхиди нигезле христиан гакыйдәсенә соңыннан кергән тәслис теориясенең Инҗилләрдә җитди дәлиле очрамый. «Өчлек» дигәнне белдергән тәслис сүзе көнбатыш телләрендә «тринити» термины белән аңлатыла. Тринити сүзе Инҗилләрнең һичкайсында телгә алынмый. Христианлык тарихында тәүге тапкыр безнең эраның II гасырында Тертуллиан тарафыннан кулланылган.

Шулай ук Яңа Гаһеднең һичбер урынында Хәзрәти Гайсәнең «Мин Тәңре» дигән сүзләре китерелми. Киресенчә, ул үзенең кол булганын әйтә.[174] Аллаһ Тәгалә Коръәни-Кәримдә дә Хәзрәти Гайсәнең кол булганлыгы турында хәбәр итә.[175] Гайсә галәйһис-сәләәм әлеге коллык сыйфаты аркасында үзен

174. Карагыз: Матфей Инҗиле, 12/18.
175. Карагыз: «ән-Ниса», 172.

кимсетелгән дип тоймый, киресенчә, Изге Китапта әйтелгәнчә, моны горурлык, хөрмәт итеп кабул итә,[176] гомерен иң югары дәрәҗәдәге коллык рухында кичерә. Хәзрәти Гайсә даими рәвештә, хәтта таң атканчы, төннәр буе Аллаһка гыйбадәт кыла. Хәлбуки, гыйбадәт кылу илаһилык үзенчәлеге түгел, киресенчә, коллык чагылышы булып тора.

Христианнар, тәслиснең Инҗилләрдәге дәлиле сыйфатында, тартып-сузып, шушы җөмләләрне телгә ала: «Гайсә, чумдырылып, судан чыккач ук, күк капусы ачылып китте, һәм ул үзенә Аллаһ рухының күгәрчен рәвешендә иңүен күрде. Күктән: “Бу – минем сөекле улым, ул – минем куанычым”, – дигән тавыш килде» (Матфей Инҗиле, 3, 16–17).

Моңа охшаш гыйбарәләр Инҗилнең башка бүлекләрендә дә очрый.[177] Ләкин игътибар белән караганда, бу җөмләләрдән өч алла яки өч укнумлы, ягъни өч элементтан гыйбарәт бер алла мәгънәсен чыгару мөмкин түгеллеген күрә алабыз.

Шуны ассызыклап китү зарур: христианнарның төп китабы булган, асылы бозылганлыгы Коръәни-Кәрим тарафыннан белдерелгән Инҗилләрдә дә ныклы, аңлаешлы дәлиле табылмаган тәслискә ышану, ничек кенә аңлатырга маташмасыннар, христианнар ни рәвешле генә расларга омтылмасыннар, Аллаһ каршында ахырзаман дине – ислам алып килгән тәүхид иман белән һич туры килми!

Башка яктан караганда, христианнарның тәңре өчен куллана торган «ата» сүзе дә бик кимсетүле яңгырый. Чөнки кеше күзлегеннән караганда начар ассоциацияләр уята торган аталар булырга мөмкин. Шул ук вакытта «ата» төшенчәсе бер бәндәчел үзенчәлек булган җенси мөнәсәбәтләрне, үзеннән соң варис калдыру сыйфатын һәм үлемне хәтерләтә, ә Аллаһ Җәллә Җәләлүһү боларның бөтенесеннән дә азат.

Аллаһ Тәгаләнең Гайсә галәйһис-сәләәмне атасыз яралтуы – искиткеч зур могҗиза. Ләкин бу хәл аның илаһ булуын таләп итми. Чөнки Хәзрәти Адәм галәйһис-сәләәм дә атасыз яралтыла. Өстәвенә аның яратылышында хәтта ана да катнашмый. Анасыз да, атасыз да яралтылган Хәзрәти Адәмгә бу сыйфаты һәм әле үзеннән Хәзрәти Хәүва да яралтылган булуы аркасында һичнинди илаһилык тагылмаган кебек, Хәзрәти Гайсәгә дә андый үзенчәлек өстәлә алмый. Әгәр Аллаһ Тәгалә бер саф кыздан атасыз бер бала яралта икән, бу исә балага түгел, шәхсән аны яралткан Аллаһка гыйбадәт кылуны, буйсыну таләп итә.

Ислам Аллаһның югары сыйфатларга ия, һичбер мәхлукка охшамаган, һәртөрле кимчелектән азат, аннан башка бер илаһ булмаган, бөеклек һәм

176. Карагыз: Матфей Инҗиле, 12/18; Ишагыя китабы, 42/1.
177. Карагыз: Иоанн, 1/1, 14.

кодрәт иясе, бердәнбер Раббы икәнлеген игълан итә. Әлеге белдерү бик төпле, кыска рәвештә, «Ихлас» сүрәсендә аңлатыла:

قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ اللَّهُ الصَّمَدُ لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ وَلَمْ يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ

**«(И, Рәсүлем!) Әйт: “Ул Аллаһ – бердәнбер. Аллаһ – Мохтаҗ булмаучы. Ул тудырмаган (һичкемнең атасы түгел) һәм тудырылмаган (һичкемнең баласы түгел). Һич беркем Аңа тиң түгел”».**

Бу кыска сүрә, тәүхиднең бөтен үзенчәлекләрен бик җыйнак шәкелдә аңлатып, Гайсә галәйһис-сәләәм кебек, туу һәм үлем белән чикле итеп яралтылган мәхлукның илаһилыкка һичбер катнашы юклыгын белдереп, тәслиснең мөмкин түгел, булмастай нәрсә икәнлеген күрсәтү өчен җитә.

Бу күзлектән караганда, Җәнабел-Хак тәслис гакыйдәсендәгеләрне катгый кисәтә:

لَقَدْ كَفَرَ الَّذِينَ قَالُوا إِنَّ اللَّهَ هُوَ الْمَسِيحُ ابْنُ مَرْيَمَ وَقَالَ الْمَسِيحُ يَا بَنِي إِسْرَائِيلَ اعْبُدُوا اللَّهَ
رَبِّي وَرَبَّكُمْ إِنَّهُ مَنْ يُشْرِكْ بِاللَّهِ فَقَدْ حَرَّمَ اللَّهُ عَلَيْهِ الْجَنَّةَ وَمَأْوَاهُ النَّارُ وَمَا لِلظَّالِمِينَ مِنْ أَنْصَارٍ

**«”Аллаһ – Мәрьям улы Мәсих ул”, – дип әйтүчеләр кяфер булдылар. Хәлбуки, Мәсих: ”И, Исраил уллары! Минем дә Раббым, сезнең дә Раббыгыз булган Аллаһка гыйбадәт кылыгыз. Кем дә кем Аллаһка ширек кушса, Аллаһ җәннәтне аңа харам кылды. Аның сыенасы урыны – Ут. Залимнәргә ярдәмчеләр юк”, – дигән иде»** («әл-Маидә», 72).

لَقَدْ كَفَرَ الَّذِينَ قَالُوا إِنَّ اللَّهَ ثَالِثُ ثَلَاثَةٍ وَمَا مِنْ إِلَهٍ إِلَّا إِلَهٌ وَاحِدٌ
وَإِنْ لَمْ يَنْتَهُوا عَمَّا يَقُولُونَ لَيَمَسَّنَّ الَّذِينَ كَفَرُوا مِنْهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ

**«Аллаһ – өчнең өченчесе», – дип әйтүчеләр кяфер булдылар. Хәлбуки, бер Аллаһтан башка илаһ юк. Әйткәннәреннән ваз кичмәсәләр, кяфер булган бу кешеләргә тилмерткеч бер газап кагылачак»** («әл-Маидә», 73).

أَفَلَا يَتُوبُونَ إِلَى اللَّهِ وَيَسْتَغْفِرُونَهُ وَاللَّهُ غَفُورٌ رَحِيمٌ

**«Аллаһка тәүбә итмәячәкләрме һәм Аңардан ярлыкау сорамаячаклармы? Аллаһ – Гафу итүче, Рәхимле»** («әл-Маидә», 74).

مَا الْمَسِيحُ ابْنُ مَرْيَمَ إِلَّا رَسُولٌ قَدْ خَلَتْ مِنْ قَبْلِهِ الرُّسُلُ وَأُمُّهُ صِدِّيقَةٌ
كَانَا يَأْكُلَانِ الطَّعَامَ انْظُرْ كَيْفَ نُبَيِّنُ لَهُمُ الْآيَاتِ ثُمَّ انْظُرْ أَنَّى يُؤْفَكُونَ

**«Мәрьям улы Мәсих – бер пәйгамбәр генә. Аңа кадәр дә пәйгамбәрләр (килеп) киткән иде. Анасы да бер тугры хатын гына. Алар икесе дә азык ашыйлар иде. Безнең дәлилләрне аларга ничек итеп бәян иткәнебезне кара. Шуннан соң аларның (моны күреп әһле китапның) ничек (хакыйкатьтән) читләшкән булуларын кара!»** («әл-Маидә», 75).

Аяти кәримәдә телгә алынган **«икесе дә азык ашыйлар иде»** гыйбарәсе Гайсә галәйһис-сәләәмнең һәм әнисенең бәндә икәнлегенә басым ясый, чөнки аларның ризык ашавы ачлык һәм туклык кебек бәндәчел сыйфатларын ассызыклап күрсәтә, Җәнабел-Хак, әлбәттә, моннан пакь һәм азат.

Шуңа карамастан, әһле китапның Гайсәгә һәм Мәрьямгә илаһлык билгеләре таккан хорафатларга бирелүе тулысынча үз наданлыклары һәм гафиллекләре белән бәйле. Югыйсә Хәзрәти Гайсә бу мәсьәләдә әһле китапка хәтта бик кечкенә дә мөмкинлек бирмәгән. Аллаһ Тәгалә әйтә:

يَوْمَ يَجْمَعُ اللَّهُ الرُّسُلَ فَيَقُولُ مَاذَا أُجِبْتُمْ قَالُوا لَا عِلْمَ لَنَا إِنَّكَ أَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ

**«Аллаһ пәйгамбәрләрне туплаган көнне: “Сезгә нәрсә дип җавап кайтардылар?” – дип әйтер, алар: “Бездә бернинди белем юк. Һичшиксез, син – бөтен яшеренгәнне белүче”, – дип әйтерләр»** («әл-Маидә», 109).

وَإِذْ قَالَ اللَّهُ يَا عِيسَى ابْنَ مَرْيَمَ أَأَنْتَ قُلْتَ لِلنَّاسِ اتَّخِذُونِي وَأُمِّيَ إِلَٰهَيْنِ مِنْ دُونِ اللَّهِ قَالَ سُبْحَانَكَ مَا يَكُونُ لِي أَنْ أَقُولَ مَا لَيْسَ لِي بِحَقٍّ إِنْ كُنْتُ قُلْتُهُ فَقَدْ عَلِمْتَهُ تَعْلَمُ مَا فِي نَفْسِي وَلَا أَعْلَمُ مَا فِي نَفْسِكَ إِنَّكَ أَنْتَ عَلَّامُ الْغُيُوبِ

**«(Шулвакыт) Аллаһ әйтте: “И, Мәрьям улы Гайсә! Син кешеләргә: “Аллаһны калдырып, мине һәм әниемне ике илаһ итегез”, – дип әйттеңме?» Ул (Гайсә) әйтте: «Син пакь! Ничек итеп мин хакым булмаган нәрсәне әйтим? Әгәр мин моны әйткән булсам, Син, һичшиксез, аны белгән булыр идең. Син минем күңелемдә булганны беләсең, мин исә Синең Затыңда булганны белә алмыйм. Син бит – бөтен яшеренне кимчелексез белүче»** («әл-Маидә», 116).

مَا قُلْتُ لَهُمْ إِلَّا مَا أَمَرْتَنِي بِهِ أَنِ اعْبُدُوا اللَّهَ رَبِّي وَرَبَّكُمْ

**«Мин аларга: “Минем дә Раббым, сезнең дә Раббыгыз булган Аллаһка гыйбадәт кылыгыз!” – дип, Син миңа әмер иткән нәрсәдән башка берни әйтмәдем…»** («әл-Маидә», 117).

Аек акыллы затлар уйлап карар: Хәзрәти Гайсә миладигә кадәр елларда яшәмичә, соңыннан туганга күрә, Аллаһка соңыннан бер өстәмә булуы мөмкинме? Иоанн Инҗилендә үзенә «Йә Раббы!» дип мөрәҗәгать ителгән Хәзрәти

Гайсәгә тагылган илаһилык кодрәте кешеләр тарафыннан хачка тарттырылып җәзаланырлык көчсезлек кадәр генәме? Чөнки Инҗилләрдә Хәзрәти Гайсәнең һич теләмичә хачка асылганын белдергән җөмләләр бар. Анда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, Хәзрәти Гайсә, үзен аркылы агачка тарттырырга алып барганда: «Аллаһым, Аллаһым! Мине ник ташладың?» – дип кычкыра (Матфей Инҗиле, 27, 46). Гаҗизлек һәм буйсынмаучанлыкны белдергән бу сүзләр бәндәчел зәгыйфьлек билгесе түгелме?

Ислам дине тәүхид мәсьәләсенә бик саклык, сизгерлек күрсәтергә куша. Тәүхид төшенчәсенә зыян китерә алырдай иң вак кына нәрсәләр дә ширек дип бәяләнә. Бер мисал китерергә уйласак, Аллаһның кушканнарын читкә кагып, үз теләк-нәфесенә буйсынган кеше турында: **«Яман теләген үз илаһы иткән»** («әл-Фуркан», 43), дип хөкем чыгарыла. Шулай ук Аллаһның хәләл дигәнен хәрәм, ә хәрәм кылганын хәләлгә әйләндерүчеләрне «раббылар», аларның мондый теләкләренә иярүчеләрне исә «аларны раббыга әйләндергән затлар» дип телгә алына. Гыйбадәтне кеше күрсенгә кылудан гыйбарәт икейөзлелек яшерен ширек буларак бәяләнә.

Тәүхид мәсьәләсенә бик сизгер мөнәсәбәт күрсәткән Коръән христианнарның ялган тәслис гакыйдәсен – өч аллага ышануны катгый рәвештә кире кага һәм моның көферлек икәнен белдерә.

Аллаһ Тәгалә, Үзенең соңгы илаһи китабы булган Коръәни-Кәримдә тәслис белән бәйле ялганга алданып адашулары сәбәпле, әһле китапны болай дип кисәтә:

يَا أَهْلَ الْكِتَابِ لَا تَغْلُوا فِي دِينِكُمْ وَلَا تَقُولُوا عَلَى اللّٰهِ إِلَّا الْحَقَّ إِنَّمَا الْمَسِيحُ
عِيسَى ابْنُ مَرْيَمَ رَسُولُ اللّٰهِ وَكَلِمَتُهُ أَلْقَاهَا إِلَىٰ مَرْيَمَ وَرُوحٌ مِنْهُ فَآمِنُوا بِاللّٰهِ
وَرُسُلِهِ وَلَا تَقُولُوا ثَلَاثَةٌ انْتَهُوا خَيْرًا لَكُمْ إِنَّمَا اللّٰهُ إِلَٰهٌ وَاحِدٌ سُبْحَانَهُ أَنْ يَكُونَ
لَهُ وَلَدٌ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ وَكَفَىٰ بِاللّٰهِ وَكِيلًا

**«И, әһле китап! Динегездә чиктән ашмагыз һәм Аллаһка карата хактан башка берни дә сөйләмәгез. Мәрьям улы Гайсә Мәсих – фәкать Аллаһның илчесе, Аның Мәрьямгә җибәргән (“Бул”) сүзе һәм Аннан – бер рух (Аллаһ тарафыннан җибәрелгән, билгеләнгән, Җәбраил тарафыннан өрелгән бер җан). Аллаһка һәм пәйгамбәрләренә иман китерегез һәм: “(Тәңреләр) өчәү!” – дип әйтмәгез. Сезнең өчен иң хәерле буларак, ваз кичегез. Һичшиксез, Аллаһ – бер генә Илаһ. Ул баласы булудан пакь. Күкләрдәге һәм җирдәге һәммә нәрсә – Аныкы гына. Бер Яклаучы буларак, Аллаһ җитә!»** («ән-Ниса», 171).

لَنْ يَسْتَنْكِفَ الْمَسِيحُ أَنْ يَكُونَ عَبْدًا لِلَّهِ وَلَا الْمَلَائِكَةُ الْمُقَرَّبُونَ وَمَنْ
يَسْتَنْكِفْ عَنْ عِبَادَتِهِ وَيَسْتَكْبِرْ فَسَيَحْشُرُهُمْ إِلَيْهِ جَمِيعًا

**«(Шуны белегез:) ни Мәсих, ни якынайтылган фәрештәләр Аллаһның колы булудан кимсенми. Кем дә кем Аңа коллыктан кимсенсә һәм тәкәбберләнсә, Ул (Аллаһ) аларны барысын бергә Үзенә туплаячак»** («ән-Ниса», 172).

لَقَدْ كَفَرَ الَّذِينَ قَالُوا إِنَّ اللهَ هُوَ الْمَسِيحُ ابْنُ مَرْيَمَ قُلْ فَمَنْ يَمْلِكُ مِنَ اللهِ شَيْئًا إِنْ
أَرَادَ أَنْ يُهْلِكَ الْمَسِيحَ ابْنَ مَرْيَمَ وَأُمَّهُ وَمَنْ فِي الْأَرْضِ جَمِيعًا وَلِلَّهِ مُلْكُ السَّمَاوَاتِ
وَالْأَرْضِ وَمَا بَيْنَهُمَا يَخْلُقُ مَا يَشَاءُ وَاللهُ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ

**«Аллаһ – Мәрьям улы Мәсих ул», – дип әйткән кешеләр кяфер булдылар. Әйт: “Ул Мәрьям улы Мәсихне, аның анасын һәм җирдә булучыларны һәлак итәргә теләсә, кем Аллаһка иң кечкенә бернәрсә белән комачау итә алыр?” Күкләрнең, җирнең һәм икесе арасындагыларның хакимлеге – Аллаһныкы гына. Ул теләгәнен бар итәр. Аллаһ – һәрнәрсәгә кодрәтле»** («әл-Маидә», 17).

Китабыбызда әүвәлрәк инде әйтелгәнчә, бик күп белгечләрнең раславына күрә, Хәзрәти Гайсәне илаһилаштыру идеологиясе христианлыкка Борынгы грек, Александрия һәм һинд философияләре тәэсирендә керә.

«Британика» энциклопедиясендә болай дип әйтелә: «Гайсә гайре табигый затлардан, элементлардан булганлыгын раслаган һичбер сүз әйтми, бәндәчел табигатьтән өстен холык-табигатькә ия икәнлеге турында да сөйләми» (V том, 636 б.).

Хәзрәти Гайсә: «Тыңла, и, Исраил кавеме! Аллаһыбыз – Раббы, бердәнбер Раббы», – дигән (Марк Инҗиле, 12, 29. Шулай ук карагыз: Матфей, 23, 8; Лука, 13, 33). Башка урыннарда мондыйрак сүзләр бар:

«Барысы курка калдылар һәм Аллаһны данладылар. “Безнең арадан бөек пәйгамбәр чыкты”, – диделәр» (Лука Инҗиле, 7/16).

«Гайсә эшләгән могҗизалы гамәлне күреп, кешеләр: “Дөньяга килергә тиеш булган пәйгамбәр, чынлап та, шушыдыр”, – диештеләр» (Иоанн Инҗиле, 6/14).

Күренгәнчә, чынлыкта христианнарның үз чыганакларындагы мәгълүматлар да Хәзрәти Гайсәнең Аллаһ колы һәм Рәсүле икәнлеген, аның илаһилыкка катнашы юклыгын исбатлау өчен җитәрлек. Ләкин Павел кебек алдар руханилар, иман пәрдәсенә төреп, дингә дошманлык кылу белән шөгыльләнәләр.

Алар Хәзрәти Гайсә турында кешеләргә ялган тарату белән генә чикләнмичә, хисапсыз ялган мәгълүматлар ярдәмендә аларны бозыклыкка тарталар, юлдан яздыралар. Шул хәлдә дә христианнар бүген үз-үзләрен инандырып, Аллаһның сөекле бәндәләре икәнлекләрен һәм җәннәткә үзләре генә керәчәкләрен алга сөрәләр. Аларның мондый карашларына Җәнабел-Хак болай дип җавап бирә:

وَقَالُوا لَنْ يَدْخُلَ الْجَنَّةَ إِلَّا مَنْ كَانَ هُودًا أَوْ نَصَارَىٰ تِلْكَ
أَمَانِيُّهُمْ قُلْ هَاتُوا بُرْهَانَكُمْ إِنْ كُنْتُمْ صَادِقِينَ

**«Алар (әһле китап): "Яһүдиләрдән яки насаралардан башка җәннәткә беркем дә кермәячәк", – диделәр. Бу – аларның буш өметләре. (И, Рәсүлем! Син аларга) әйт: "Әгәр сез тугры кешеләр булсагыз, дәлилләрегезне китерегез!"»** («әл-Бәкара», 111).

وَقَالَتِ الْيَهُودُ وَالنَّصَارَىٰ نَحْنُ أَبْنَاءُ اللَّهِ وَأَحِبَّاؤُهُ قُلْ فَلِمَ يُعَذِّبُكُمْ بِذُنُوبِكُمْ بَلْ أَنْتُمْ بَشَرٌ مِمَّنْ
خَلَقَ يَغْفِرُ لِمَنْ يَشَاءُ وَيُعَذِّبُ مَنْ يَشَاءُ وَلِلَّهِ مُلْكُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَمَا بَيْنَهُمَا وَإِلَيْهِ الْمَصِيرُ

**«Яһүдиләр һәм насаралар: "Без – Аллаһның улларыбыз һәм Аның сөеклеләребез", – диделәр. Әйт: "Ул ни өчен соң гөнаһларыгыз сәбәпле сезгә җәза бирә? Юк! Сез – Аның яралтканнары арасыннан кешеләрсез генә. Ул теләгәнен ярлыкар. Теләгәнен исә җәзаландырыр. Күкләрнең, җирнең һәм икесе арасындагыларның хакимлеге – Аллаһныкы гына. Кайту да Аңа гына"»** («әл-Маидә», 18).

Христианнар кереп баткан әлеге ачы, аяныч язмыш аларның да, яһүдиләр кебек, үзләренә иңдерелгән илаһи китапны үз теләкләренә ярашлы рәвештә бозганлыклары, аның эчтәлеген кешеләштергәнлекләре белән бәйле, чөнки мондый гамәл нәфесләренә тагын да матуррак, шәбрәк итеп күренә, үзләре кыла башлаган гаеп эшләрне илаһи китапларына өстәп, алар бу эшләрне канунлаштыру мөмкинлеген ала. Тик бу хәл, табигый ки, ахирәт бәхетен югалтуларына нигез була. Хәтта Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хөрмәтле өндәве дә гафләттән уята алмаячак дәрәҗәдә ялганга баткан бик күп әһле китапның хәле никадәр үкенечле!

Нәҗран төбәге христианнарыннан бер делегация Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм янына килеп: «Коръәни-Кәрим дә Хәзрәти Гайсәнең атасыз туганлыгын кабул иткәнгә күрә, ул Аллаһ буладыр!» – диләр.

Шуннан соң түбәндәге «мөбахәлә» (хаклыкны ачыклау өчен, бер-береңне орышу, ләгънәт яудыру) аяте иңә:

فَمَنْ حَاجَّكَ فِيهِ مِنْ بَعْدِ مَا جَاءَكَ مِنَ الْعِلْمِ فَقُلْ تَعَالَوْا نَدْعُ أَبْنَاءَنَا وَأَبْنَاءَكُمْ وَنِسَاءَنَا وَنِسَاءَكُمْ وَأَنْفُسَنَا وَأَنْفُسَكُمْ ثُمَّ نَبْتَهِلْ فَنَجْعَلْ لَعْنَتَ اللَّهِ عَلَى الْكَاذِبِينَ

**«(И, Рәсүлем!) Сиңа гыйлем килгәннән соң, кем дә кем аның хакында синең белән тартышса, әйт: “Килегез, улларыбызны һәм улларыгызны, хатыннарыбызны һәм хатыннарыгызны, үзебезне һәм үзегезне чакырыйк та, Аллаһның ләгънәте ялганчылар өстенә төшсен, дип дога кылыйк!” – диген»** («Әли Гыймран», 61).

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, аяти кәримә кушканча тәкъдим ясаса да, Нәҗран христианнары аны кабул итә алмый. Мөселманнар химаясенә керүгә ризалашуны белдергән килешү имзалап, алар үз дәүләтләренә кайтып китә.

Аллаһ Тәгалә әһле китапны кисәтү максатында болай ди:

يَا أَهْلَ الْكِتَابِ لِمَ تَكْفُرُونَ بِآيَاتِ اللَّهِ وَأَنْتُمْ تَشْهَدُونَ

**«И, әһле китап! Ни өчен Аллаһның аятьләрен (чынбарлыкка) шаһитлык иткән хәлдә инкяр итәсез?»** («Әли Гыймран», 70).

يَا أَهْلَ الْكِتَابِ لِمَ تَلْبِسُونَ الْحَقَّ بِالْبَاطِلِ وَتَكْتُمُونَ الْحَقَّ وَأَنْتُمْ تَعْلَمُونَ

**«И, әһле китап! Ни өчен хакны ялган белән каплыйсыз һәм белгән хәлдә хакны яшерәсез?»** («Әли Гыймран», 71).

قُلْ يَا أَهْلَ الْكِتَابِ لِمَ تَصُدُّونَ عَنْ سَبِيلِ اللَّهِ مَنْ آمَنَ تَبْغُونَهَا عِوَجًا وَأَنْتُمْ شُهَدَاءُ وَمَا اللَّهُ بِغَافِلٍ عَمَّا تَعْمَلُونَ

**«И, әһле китап! (Чынбарлыкка) шаһит булган хәлегездә ни өчен иман китергән кешене Аллаһ юлыннан яздырасыз һәм аны бозасыз? Аллаһ сезнең ни кылганнарыгыздан гафил түгел»** («Әли Гыймран», 99).

Христианнар күргән, белгән хакыйкать, дигәндә, аяти кәримәләрдә аларның диннәренең үзгәртелгәнлеге, бозылганлыгы, шунлыктан Җәнабел-Хак тарафыннан ахыргы илаһи китап булган Коръәни-Кәрим белән Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең җибәрелгәнлеге белдерелә. Христианнар үзләре моны ачып салмаса да, Аллаһ Тәгалә ап-ачык рәвештә аңлатып бирә:

الَّذِينَ آتَيْنَاهُمُ الْكِتَابَ يَعْرِفُونَهُ كَمَا يَعْرِفُونَ أَبْنَاءَهُمْ وَإِنَّ فَرِيقًا مِنْهُمْ لَيَكْتُمُونَ الْحَقَّ وَهُمْ يَعْلَمُونَ

**«Без үзләренә китап биргән кешеләр аны (Мөхәммәд галәйһис-сәләәмне) үз улларын белгән кебек беләләр. Ләкин алардан бер җәмәгать хакны яшерә»** («әл-Бәкара», 146).

إِنَّ الَّذِينَ يَكْتُمُونَ مَا أَنْزَلْنَا مِنَ الْبَيِّنَاتِ وَالْهُدَىٰ مِنْ بَعْدِ مَا
بَيَّنَّاهُ لِلنَّاسِ فِي الْكِتَابِ أُولَئِكَ يَلْعَنُهُمُ اللّٰهُ وَيَلْعَنُهُمُ اللَّاعِنُونَ

**«(Ләкин шуны белсеннәр:) һичшиксез, Китапта кешеләргә бәян иткәнебездән соң, Без иңдергән ап-ачык дәлилләрне һәм һидәятне яшерүчеләрне Аллаһ ләгънәт итә, аларны бөтен ләгънәт итүчеләр дә ләгънәтли»** («әл-Бәкара», 159).

Аллаһ катында кабул ителәчәк бердәнбер ислам диненнән мөмкин кадәр ерак торырга тырышкан әһле китапка нинди үкенеч! Ә менә алар арасыннан олуг хакыйкатьне аңлап, Аллаһка чын мәгънәсендә буйсынып, гыйбадәткә юнәлгәннәр никадәр бәхетле! Аяти кәримәдә әһле китапның, ахырзаман җитеп, Хәзрәти Гайсә җир йөзенә кире иңдерелгәннән соң, барчасы бергә иман китерәчәге турында хәбәр ителә:

وَإِنْ مِنْ أَهْلِ الْكِتَابِ إِلَّا لَيُؤْمِنَنَّ بِهِ قَبْلَ مَوْتِهِ وَيَوْمَ الْقِيَامَةِ يَكُونُ عَلَيْهِمْ شَهِيدًا

**«Һичшиксез, әһле китаптан берсе-бер калмыйча, һәммәсе дә үлеменнән алда аңа иман итәчәк. Кыямәт көнендә исә ул аларга каршы шаһит булачак»** («ән-Ниса», 159).

Христианнарның бүген үзләре кереп баткан ялгыш юлдан баш тартмауларында бердәнбер сәбәп исә Инҗилләре белән бәйле. Аларны язучылар Инҗилләрне үз теләкләренә ярашлы рәвештә шул хәлгә китереп җиткергән ки, чын Инҗили-Шәрифне җибәргән Җәнабел-Хак куркыныч хәбәрен ирештерә:

فَوَيْلٌ لِلَّذِينَ يَكْتُبُونَ الْكِتَابَ بِأَيْدِيهِمْ ثُمَّ يَقُولُونَ هَذَا مِنْ عِنْدِ اللّٰهِ لِيَشْتَرُوا
بِهِ ثَمَنًا قَلِيلًا فَوَيْلٌ لَهُمْ مِمَّا كَتَبَتْ أَيْدِيهِمْ وَوَيْلٌ لَهُمْ مِمَّا يَكْسِبُونَ

**«Үз куллары белән китап язган, шуннан соң аны юк бәягә сатып алыр өчен, “Бу – Аллаһтан” дип әйтүчеләргә ни үкенеч! Куллары белән язган нәрсәләре өчен аларга ни үкенеч һәм кәсеп иткән нәрсәләре өчен аларга ни үкенеч!»** («әл-Бәкара», 79).

Алар кылган гамәл – илаһи китапка кул тыгу мәсьәләсе хәтта пәйгамбәрләр өчен дә тыелган бер эш булып тора. Бу мәсьәләдәге илаһи фәрман хәтта Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебезгә бәйле рәвештә дә яңгырый. Җәнабел-Хак әйтә:

وَلَوْ تَقَوَّلَ عَلَيْنَا بَعْضَ الْأَقَاوِيلِ لَأَخَذْنَا مِنْهُ بِالْيَمِينِ ثُمَّ
لَقَطَعْنَا مِنْهُ الْوَتِينَ فَمَا مِنْكُمْ مِنْ أَحَدٍ عَنْهُ حَاجِزِينَ

**«Әгәр ул (Пәйгамбәр) Безгә карата нинди дә булса сүзләр уйлап чыгарган булса иде. Без аның уң кулын тотар идек. Шуннан соң шаһ тамырын ярыр идек (Аны яшәтмәс идек). Шулвакыт сезнең арагыздан аны берәү дә коткара алмас иде!»** («әл-Хакка», 44–47).

Аллаһ Тәгалә шулай ук:

إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللَّهِ الْإِسْلَامُ

**«Һичшиксез, Аллаһ хозурында (хак) дин – ислам!..»** аяте белән («Әли Гыймран», 19), соңгы һәм хак дин буларак, ислам хөкемнәренең кыямәткәчә мәңге гамәлдә калачагына басым ясый. Башка дин инде килмәячәк. Бу яктан караганда, Коръәни-Кәрим кеше тарафыннан тыкшынуларга каршы илаһи сак астына алынган. Хак Тәгалә әлеге хакыйкатьне:

إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ

**«Һичшиксез, Коръәнне Без иңдердек һәм Без аны саклыйбыз!»** – дип анык белдереп куя («әл-Хиҗр», 9).

### Дүрт Инҗилнең үзенчәлекләре

Җәнабел-Хак Гайсә галәйһис-сәләәмгә җибәргән Инҗили-Шәриф, әлбәттә, хак һәм һәр мөэминнең «иман шартлары», ислам рөкеннәре арасында телгә алынган «вә күтүбиһи» (һәм китапларына да инандым) гыйбарәсенә керә. Бу мәсьәләгә кагылышлы рәвештә, Аллаһ Тәгалә Коръәни-Кәримдә, теге яки бу хакта хәбәр итәр алдыннан, «Тәүратта һәм Инҗилдә дә без инде язган кебек...» дип искә ала. Димәк, асыл Инҗил Коръәни-Кәрим кебек үк илаһи һидәяткә юл күрсәтүче булып тора.

Ләкин әүвәлрәк урыннарда төрле мәсьәләләр белән бәйле рәвештә телгә алынганча, христиан чиркәве Гайсә галәйһис-сәләәмнең тормышы һәм ул өйрәткән хөкемнәр мәсьәләсендә гаять җитди күләмдә кыскарту белән шөгыльләнгән. Бу кыскарту эшендә иң беренче булып төп өлеш кисеп ташлана: диннең нигезе булган «тәүхид», «бераллалык» христианлыктан алып ыргытыла.

Бүгенге христианлыктагы вәхи системасы, исламдагы вазгыятьнең киресе буларак (христианнарның күбесенең күзаллавына каршы килеп), язма рәвештә тапшырган бер төркем кешеләрнең шаһитлыгыннан гыйбарәт. Христиан

галимнәре үзләре дә раслаганча, бүген христианлык Гайсә галәйһис-сәләәм яшәгән чорны күреп тасвирлаган ныклы, ышанычлы мәгълүматка ия түгел.

Чыннан да, бүген Изге Китап белән бәйле иң мөһим проблемаларның берсе Хәзрәти Гайсәгә кадәрге чор китапларын туплаган «Иске Гаһед» өлешенең оригинал теле – иврит, Хәзрәти Гайсәдән соңгы чор китапларын берләштергән «Яңа Гаһед» өлеше грекча булуында. Югыйсә, ул икенче өлешнең дә асыл теле – иврит теле. Грекчага тәрҗемәләре табылган бу Инҗилнең асыл нөсхәләре юк. Бу очракта исә тәрҗемәләрнең асыл нөсхәне никадәр дөрес тапшыруын, төп текстка никадәр нисбәтле булуын ничек расларга мөмкин?

Хәзер кулда булган Инҗилләрнең, Матфей Инҗиленнән кала, иң иске нөсхәләре грекча язылган. Христиан чыганаклары исә Хәзрәти Гайсәнең иврит-арамей телендә сөйләшкәнлеген һәм вәгазь-нәсыйхәтләрен шушы телдә алып баруын хәбәр итә. Ул очракта Инҗилләрнең теле һәм Гайсә галәйһис-сәләәм сүзләре темасы күтәрелгәндә, аларның, иң аз дигәндә дә, оригинал нөсхәләренең Хәзрәти Гайсә теле белән язылган булуы һәм күз карасыдай сакланырга тиешлеге таләп ителмиме? Ләкин бүген Инҗилләр дә, Гайсә галәйһис-сәләәмнең үз сүзләре дә аның туган телендә язылмаган.

Тәүге Инҗил караламаларының ивритчә язылуына карамастан, аларның юкка чыгуы, ивритчә язылган башка Инҗилләрнең дә шундук грекчага тәрҗемә ителеп, иврит телендәге нөсхәләренең юк ителүе, хәтта «Яңа Гаһед» белән «Иске Гаһед»нең грекчага тәрҗемә ителеп, Изге Китапның тулысынча грек телендә язылуы борынгы грек мәдәниятенең христиан мәдәниятенә шактый дәрәҗәдә йогынты ясаганлыгын күрсәтә. Мондый вазгыятьтә христианлыкка кадәрге грек философиясе кебек грек мәдәнияте дә бу дингә, әлбәттә, тәэсир итми калмый, аны боза һәм үз принципларына туры килгәнчә бик күп кул тыгып, үзгәртеп, илаһи тәүхид тарафын юкка чыгара. Шуңа күрә аяти кәримәдә:

**«...Куллары белән язган нәрсәләре өчен аларга ни үкенеч һәм кәсеп иткән нәрсәләре өчен аларга ни үкенеч!»** – дип әйтелә дә («әл-Бәкара», 79).

Янә шуңа күрә дә без дәлилләнгән гыйлем дип йөрткән хикмәтләр, хакыйкатьләр белән бүгенге Инҗилләр арасында бик зур аермалыклар бар. Әйтик, планетаның әйләнүен мөселманнарның хезмәтләреннән укып белеп, моны ышанып кабул иткән Галилей, әлеге хакыйкатьне әйләнә-тирәсендәгеләргә сөйләгәч, чиркәү даирәләре, Инҗилдәге мәгълүматлар белән ярашмаганга күрә, бу хәлгә катгый каршы чыга һәм аңа: «Йә сөйләгәннәреңнән ваз кичәсең, йә сине үтерәбез!» –дип яный.

Дөресен сөйләгән өчен үлем куркынычы янаган Галилей исә бичара хәлдә калып: «Сез әйткәнчә булсын!» – ди, үзенә чыгарылган хөкемгә каршы бары: «Сез әйләнми, дисәгез дә, җир әйләнә!» – дип үз алдына мыгырдanудан ерак китә алмый.

Әнә шул аермалыклар аркасында, Инҗилләр эчтәлегендәге каршылыкларны саклап калу өчен кайгырып булса кирәк, христианлыкка караган дини китаплар күп очракта таркау кисәкләр хәлендә карала. Инҗилләрнең һичкайсы бербөтен басма рәвешендә укылмый. Хәтта мәзһәп һәм аерым җәмәгатьләр дә теге яки бу китапны сайлап ала. Хәтта менә шушы хәл дә, акылы булган кешеләр өчен, Изге Китап кисәкләренең күчерелү, тапшырылу ягыннан да дөреслеккә туры килмәгәнен танудан башка мантыйкка сыешлы юл калдырмый.

Әйтик, Э. Якоб Инҗилләрдәге риваять сөрешенең ахырга таба чып-чын әкият рәвешен алуына игътибар юнәлтә. Морис Бюкай болай дип яза:

«...Изге Китап җаннары теләгән кадәр текстны үзгәрткән кешеләрнең безгә калдырырга омтылган сүзләреннән гыйбарәт. Шуңа күрә дә китапларның кеше кулы белән язылуы турындагы иң төп темаларга һич тукталмаслар, шундук узып китәрләр. Әлеге китаплар кешеләр тарафыннан бик күп тапкыр бәндәчел фильтр аша уздырылган берәр нәрсә кебек, күп тапкыр тыкшынуларга, кул тыгуларга дучар ителә. Хисапсыз диярлек ялгыш мәгълүматларга анализ ясалмый, алар барысы да сүзсез генә узып кителә. Ләкин хәтта аерым бер кеше китабында да дөрес дип бәяләнә алмаслык бу хәл – изге дип саналган китап өчен никадәр аяныч күренеш!..».

Әлеге хакыйкатьне шушы рәвешле аңлатучылар табылмаса да, Аллаһ Тәгалә җибәргән китаплардан берсе булган Инҗилнең үзгәртелүен, бозылуын белдерү өчен, монысы да җитәрлек. Бу хакыйкатьне аңлату һәм Мөхәммәд өммәтен шундый ук гафләт һәм бозыклык сазлыгына төшүдән кисәтү өчен, Җәнабел-Хак болай ди:

مِنَ الَّذِينَ فَرَّقُوا دِينَهُمْ وَكَانُوا شِيَعًا كُلُّ حِزْبٍ بِمَا لَدَيْهِمْ فَرِحُونَ

**«Шулардан ки (ерак торыгыз), кемнәр диннәрен бүлгәләделәр һәм фиркаләр булдылар. Һәрбер фирка үзләрендә булганга сөенә»** («әр-Рум», 32).

Югарыда әйтелгәннәрдән аңлашылганча, исламга кадәрге бөтен илаһи диннәр һәм аларның китаплары кебек, Җәнабел-Хак Гайсә галәйһис-сәләәмгә иңдергән дин һәм аның китабы булган Инҗили-Шәриф тә христианнар тарафыннан аятьтә әйтелгәнчә үзгәртелгән. Бу күзлектән караганда, бүгенге дүрт Инҗилнең дә асыл, чын Инҗили-Шәриф белән һич бәйләнеше юк.

**Матфей**

Рим империясе исеменнән салым җыючы бер яһүди буларак, Матфей Инҗилен яһүди чыгышлы христиан җәмәгать өчен язган. Бу Инҗилнең б.э. 65 нче елларында язылуы әйтелә. Әлеге Инҗил бер яктан Хәзрәти Гайсәнең яһүдләр тарихы үсешен тулысынча төгәлләвен исбатлау максаты белән иҗат

ителә. Ләкин бер төркем тикшеренүчеләр хәзер билгеле Матфей Инҗиле Матфей исемле зат тарафыннан түгел, ә исеме билгесез бер палестиналы яһүди тарафыннан язылган, дигән фикерне алга сөрә. Чыннан да, игътибар белән караганда, бу Инҗилнең, христианлыктан бигрәк, иудаизмга хас уй-фикер системасын чагылдыруы күзгә ташлана.

Матфей Инҗиле язылганда, Марк язган китаптан да файдаланылган. Хәвари дип кабул ителгән Матфейның хәвари булмаган бер зат тарафыннан язылган Инҗилне куллануы исә чынлыкта мәгънәсезлек булып тора. А. Трикот бу Инҗил хакында: «Грек киеме кидерелгән әлеге китап, ите-сөяге һәм рухы белән яһүди. Анда иудаизм эзләре бар. Һәм ул яһүд диненең ап-ачык билге-хасиятләренә ия».

**Марк**

Марк башта бер кыска Инҗил язган, аннары шуны киңәйткән. Ләкин соңрак бу Инҗилнең дүрттән өче югалган һәм Марк, әүвәлге тупланмаларын кабат файдаланып, хәзер безгә билгеле Инҗилен язган. Мондый вазгыятьтә христиан авторларның, Маркны Петр һәм Павелның шәкерте дип расларга маташып, ул язган Инҗилне ышанычлы һәм хөрмәткә лаек дип ышандырырга тырышулары нигезсез.

Һичшиксез, Марк Инҗиленең чын авторы турында да сораулар бик күп. Кайберәүләр фикеренчә, бу Инҗилне Марк түгел, Петр язган. Чынлыкта Марк Хәзрәти Гайсәне күрмәгән дә, аның сөйләгәннәрен тыңламаган да. Язган нәрсәләре дә – башкалардан ишетеп белгәннән хәтерендә калдырганнары. Бу язмаларның исә һичбер тәртибе юк, алар хисапсыз хаталар белән тулы. Җөмләләренең төзелешендә, тәртибендә хәтта бераз гына булса да хронологик эзлеклелек әсәре юк.

Б.э. 63–70 еллары арасында язылганлыгы әйтелгән бу Инҗилнең авторы турында М.П. Роже: «Марк – гаять тәҗрибәсез язучы. Бөтен Инҗил авторларының иң түбән дәрәҗәлесе», – дип яза.

**Лука**

Өченче Инҗилне язган Луканың төп һөнәре табиблык була. Инҗилнең «Рәсүлләрнең эшләре» дигән китабын да шушы зат язган.

Лука, греклар өчен Инҗил язуны максат итеп, кулына каләм ала. Ләкин аның китабында тарихи ялгышлыклар һәм хаталар тулып ята. Инҗилен язганда, Лука Марк китабын файдалана, шулай ук илаһи булмаган башка хезмәтләрне, хәтта халык авыз иҗаты чыганакларын да куллана, берничә әкият тә өстәп җибәрә. Шунлыктан Чарльз Канненгиссер аны: «Чып-чын романчы!» – дип атаган.

Хәзрәти Гайсә турында сөйләгәндә, чыгышы белән грек булган Лука, грек тарихчыларының уй-хыялларда күзаллап бәян иткән берәр грек батырын тасвирлау өчен куллана торган өслүбен файдалана, китабын әдәби роман мантыйгына нигезләнеп иҗат итә. Бу үзенчәлекләр исә аның илаһи китап була алмавын беренче карауда ук ачып бирә. Ягъни Лука Инҗиле дә бәндә мөмкинлекләрен илаһи вәхи урынына тәкъдим итәргә маташкан бер китаптан гына гыйбарәт.

**Иоанн**

Дүртенче Инҗил – Иоанныкы. Хәзрәти Гайсәнең дусты һәм хәварие, Зәбәдә белән Саломе улы булган Иоанн язган дигән фикер алга сөрелә. Ләкин тикшеренүчеләр бу Инҗилдә Александрия фәлсәфә мәктәбеннән алынган һәм яңа грек фәлсәфәсенә таянган логик фикернең ачык күренүенә нигезләнеп, аның Иоанн исемле башка бер шәхес тарафыннан язылуын сөйли, чөнки хәвари Иоанның грек фәлсәфәсендә тәрбияләнүе һәм аның йогынтысында калып, моны хәтта Инҗилдә дә чагылдыруы мөмкин түгел. Икенче яктан исә, бу Инҗилне язган Иоанның максаты Хәзрәти Гайсәнең илаһилыгын исбатлаудан гыйбарәт булуы да авторның Рухуллаһка чын-чынлап иман китергән бер хәвари түгеллеген раслый.

Б.э. 90–110 нчы елларында язылган дип саналган Иоанн Инҗилендә вәхи белән бәйле бернинди дә мәгълүмат табып булмый. Әлеге Инҗилдә хәвариләр Хәзрәти Гайсәгә «Йә, Раббы!» дип мөрәҗәгать итә. Шуңа күрә Иоанн христианлыкны үзгәрткән яһүди Павел туктаган урыннан эшне дәвам итүче зат сыйфатында карала ала. М.П. Роже Иоанн язган бу Инҗил турындагы фикерен бик анык белдерә: «Синоптик Инҗилләр (бер-берсенә охшаган тәүге өч Инҗил – Матфей, Марк һәм Лука Инҗиле) Гайсәнең сүзләрен тәэсирле, аның сөйләшү өслүбенә якын рәвештә тапшыргандa, Иоаннықында һәрнәрсә авторның фикеренә күмелеп кала. Бу күренеш шул дәрәҗәгә җитә ки, кайвакыт үз-үзебездән: “Сөйләүче Гайсәме, әллә аның сүзләре Инҗилне язучының үз караш-фикерләре белән сиздермичә генә киңәйтеләме?” – дип сорарга мәҗбүр хәлдә калабыз!»

Инҗилләрнең мондый сәер хәле кайбер христиан руханиларының үзләре тарафыннан да таныла. Әйтик, өченче гасырда манихеизм тарафдары булган Таусте Инҗилләрнең авторлары турында: «Инҗилләрнең Гайсә дә, хәвариләр дә түгел, ә күп очракта соңыннан бер төркем билгесез затлар тарафыннан язылганлыгын һәм бу кешеләр тарафыннан, үзләре күрмәгән нәрсәләргә башкаларның ышанмаячагын белгәнлектән, хикәятләренең баш исеменә хәвариләр яки аларга караган затларның исемнәре куелганлыгын һәркем белә», – дип әйтә.

Хәзрәти Гайсәгә иңдерелгән, тик хәзерге вакытта табылмаган чын Инҗилнең исә мондый булмаганлыгын һәм аның тәкъва бәндәләр өчен һидәят

һәм үгет-нәсыйхәт китабы итеп җибәрелгәнлеген Коръәни-Кәрим болай дип раслый:

وَقَفَّيْنَا عَلَى آثَارِهِم بِعَيسَى ابْنِ مَرْيَمَ مُصَدِّقًا لِّمَا بَيْنَ يَدَيْهِمِنَ التَّوْرَاةِ وَآتَيْنَاهُ الإِنْجِيلَ فِيهِ هُدًى وَنُورٌ وَمُصَدِّقًا لِّمَا بَيْنَ يَدَيْهِمِنَ التَّوْرَاةِ وَهُدًى وَمَوْعِظَةً لِّلْمُتَّقِينَ

**«Алар артыннан, Тәүратта иңдерелгәннәрнең хаклыгын раслаучы итеп, Без Мәрьям улы Гайсәне җибәрдек. Һәм тәкъвалык ияләре өчен һидәят вә нәсыйхәт булсын дип, аңа үзендә һидәят һәм нур булган, үзеннән алда Тәүратта иңдерелгәннәрнең хаклыгын раслаган Инҗилне бирдек»** («әл-Маидә», 46).

Диннәре бозылганнан соң җибәрелгән ахырзаман дине исламны кабул итеп, Хак Тәгаләнең әмеренә буйсынган очракта, әһле китапны гафу итәчәген Җәнабел-Хак анык белдереп куя:

وَلَوْ أَنَّ أَهْلَ الْكِتَابِ آمَنُواْ وَاتَّقَوْاْ لَكَفَّرْنَا عَنْهُمْ سَيِّئَاتِهِمْ وَلأَدْخَلْنَاهُمْ جَنَّاتِ النَّعِيمِ

**«Һичшиксез, әгәр әһле китап иман китерсә һәм сакланса, Без аларны (элекке) яман эшләреннән пакьләр идек, аларны нәгыйм җәннәтләренә кертер идек»** («әл-Маидә», 65).

Моңа кадәр дә югарыда язганыбызча, бу дүрт Инҗилдән кала тагын бер атаклы Инҗил бар. Анысы – Варнава Инҗиле. Варнава Хәзрәти Гайсәнең якын хәвариләреннән була, тәүхид гакыйдәсен тота. Шуңа күрә бераллалык иманын яклаган Варнава тарафдарлары белән тәслис гакыйдәсен сайлап, хак юлдан тайпылган Павел яклылар арасында бик зур каршылыклар килеп чыга.

Варнава Инҗилен башкаларыннан аерып торган үзенчәлекләр:

1. Хәзрәти Гайсә Тәңре дә, Тәңренең улы да түгел. Ул – Аллаһ Тәгаләнең кешеләргә җибәргән бер пәйгамбәре.

2. Хәзрәти Ибраһим галәйһис-сәләәм корбан итеп улы Исхак галәйһис-сәләәмне түгел, ә Исмәгыйль галәйһис-сәләәмне чалырга тели.

3. Хәзрәти Гайсә хачка тарттырып асылмаган.

4. Күтеп алыначак Мәсих – Фараклит ул, ягъни Хәзрәти Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләм.

### Дүрт Инҗилдәге каршылыклар

Бу темага керешеп киткәнче, шуны хәтергә төшерик: җир йөзендәге бөтен диннәрдән бары ислам гына христианлыкның төп иман шарты – Хәзрәти Гайсәнең атасыз килеш, гыйффәтле һәм диндар саф кыздан туганлыгын

кабул итә. Ислам пәйгамбәре Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә сәхабәләренә Хәзрәти Гайсә турында Аллаһның олуг пәйгамбәре булган һәм җаһиллек сазлыгына баткан кешелеккә хак юлны күрсәтү өчен җибәрелгән, дип сөйли. Ислам Хәзрәти Гайсә өндәгән хак дингә һичкайчан тел тидерми, киресенчә, Гайсә галәйһис-сәләәмгә, аның анасы Мәрьямгә һәм Инҗилгә инану һәм хөрмәт тиешлегенә игътибар юнәлтә. Тик әлеге хөрмәтле мөнәсәбәт, ышану Хәзрәти Гайсәнең һәм ул алып килгән диннең бозылмаган, саф, асыл хәлен күздә тота.

Кыскача менә шуларны искә төшереп алгач, асыл сыйфатларын югалткан хәзерге Инҗилләрне тикшерүгә, бәяләүгә күчә алабыз.

Бу дүрт Инҗилнең язылу датасы мәсьәләсендә хәтта ике генә булса да авторның уртак фикергә килгәне юк. Бу китапларны Гайсә галәйһис-сәләәм үзе күрмәгән дә, яздырмаган да. Шуңа күрә алардагы хисапсыз хаталар, каршылыклар һәм бозылган урыннарның һәрберсен табып та бетереп булмый. Чыннан да, кеше кулы тыгылу аркасында изгелектән, бөеклектән ерагайган Инҗилләр һич аңлашылмый һәм бер-берсенә каршы килә торган мәгълүматлар белән тулы.

Мондый каршылыкларның кайбер иң мөһимнәренә тукталыйк:

* Бер үк вакыйгалар төрле Инҗилләрдә, хәтта бер үк Инҗилдә дә ике, өч яки тагын да күбрәк рәвештә һәм бер-берсенә каршы килә торган итеп тасвирлана. Җәнабел-Хакның кешеләргә теге яки бу вакыйганы шул рәвешле хакыйкатькә туры килми торган итеп бәян кылмаячагы – шиксез.

* Марк һәм Иоанн Инҗилләре Хәзрәти Гайсәнең нәсел-нәсәбе турында бернәрсә дә хәбәр итми, ә Матфей белән Лука Инҗиле аның нәсел шәҗәрәсен сурәтли. Ләкин Матфей Инҗиле, Хәзрәти Гайсәдән Хәзрәти Ибраһимгә кадәр 40 кеше санаса, Лука Инҗиле 55 кешене искә ала. Шулай ук Лука Инҗиле, шәҗәрәне Хәзрәти Адәмгә кадәр дәвам итеп, тагын 20 кеше өсти һәм гомуми санны 75кә җиткерә. Матфей исә Хәзрәти Ибраһимнән әүвәлге буыннар турында бернинди дә мәгълүмат бирми (Матфей Инҗиле, 1/17; Лука Инҗиле, 3/23–38).

Гайсә галәйһис-сәләәмнең Ибраһим галәйһис-сәләәмгә кадәр шәҗәрәсендә Матфейның 40 кеше санавы Лукада күрсәтелгән 15 кешене онытуы сәбәпле түгел, исемнәрне тикшереп караганда, аларның бер-берсеннән аерылуы, охшаш исемнәрнең дә төрле буында очравы күзгә ташлана.

Мондый каршылыклар хәтта аерым бер кеше тарафыннан язылган китапларда да кабул ителә алмаслык, җитди кимчелек булып тора. Пәйгамбәрләрне күреп, алар исән-сау чакта илаһи китапларына шаһит булган килеш тә, «могҗиза» рәвешендә бик күп дәлилләр сораган адәм баласының бүгенге дәлилсез, таянычсыз, нигезсез, каршылыклар тулып яткан китапларны кабул итеп, шуларга иман китерүен нинди сүзләр белән аңлатырга, ничек бәяләргә?

* Матфей Инҗиленә күрә, Хәзрәти Яхъяның «Ильяс» булганлыгы әйтелсә (Матфей Инҗиле, 11/14), Иоанн Инҗилендә алай түгеллеге телгә алына (Иоанн Инҗиле, 1/21).

* Яхъя галәйһис-сәләәмнең Хәзрәти Гайсә белү-белмәве мәсьәләсендә аңлатмалар төрлечә. Яхъя галәйһис-сәләәмнең үтерелүе дә Матфей һәм Марк китапларында шактый киң тасвирланса, Иоаннда бу тема бер-ике җөмлә белән узып кителгән (Иоанн Инҗиле, 19/28–30; Матфей Инҗиле, 27/32–56; Марк Инҗиле, 15/33–41).

* Гайсә галәйһис-сәләәмнең хәвариләре белән очрашуы һәм аларны үз янына алуы мәсьәләсендә Иоанн китабы һәм башкаларныкы арасында бер-берсеннән ерак, бик аерылып торган аңлатмалар очрый (Лука Инҗиле, 5/1–17; Иоанн Инҗиле, 1/35–51; Матфей Инҗиле, 4/18–22).

* Хәзрәти Гайсә Сур һәм Сайда төбәгенә килгән чакта, җенләнгән кызын савыктыру өчен пәйгамбәрдән ярдәм сораган хатынның милләте һәм дәүләте турында бер-берсенә ап-ачык каршы килә торган мәгълүматлар урын алган. Әлеге хатынның, Матфей китабына күрә, кенанлы (Матфей Инҗиле, 15/21–22), Маркка күрә исә, грек булуы (Марк Инҗиле, 7/26) – илаһи дип саналган китаплар өчен гаҗәп, көлке нәрсә. Хәтта кеше дә туган җирен бутамаганда, бөтен кимчелекле сыйфатлардан азат Яралтучының үзе яралткан бер мәхлукның дәүләтен бутавы мөмкинме? Әлбәттә, юк!

Шушы хәл дә Инҗилләрнең бер-берсен белмәгән кешеләр тарафыннан үз мәдәниятләре дәрәҗәсенә һәм шәхси теләк-ниятләренә күрә язылган каршылыклы мәгълүматлар белән тулы икәнен күрсәтеп тора.

* Гайсә галәйһис-сәләәм Инҗилләрдә илаһилаштырылып искә алынуына карамастан, бик күп урында аны «адәм баласы» һәм «Раббының колы» дип атыйлар (Матфей Инҗиле, 12/17–18; Пәйгамбәрләрнең эшләре, 3/13, 4/27–28). Бер үк кешенең Аллаһ улы да, кеше баласы да булуын ничек аңлатырга мөмкин? Бу очракта бары: «Кеше = Аллаһ ул», – дип әйтү генә таләп ителә, ә бу хакта хәтта сүз куерту да урынсыз, чөнки Аллаһ – яралтучы, кеше исә яралтылган зат булып тора.

Моны аңлаган христианнар, Инҗилләрдә очраган «Аллаһның улы» тәгъбирен Аллаһның Хәзрәти Гайсә белән кушылып, аның тәненә керүе һәм шунда урнашып, кешеләргә аның гәүдәсендә килеш күренүе, әнә шул сәбәпле Гайсә галәйһис-сәләәмнең илаһилашуын бик наданнарча, җаһилләрчә аңлатырга маташалар. Ә моның белән килешү исә Аллаһның иң бөек һәм һәр кимчелектән азат булу сыйфаты белән һичничек туры килми.

Инҗилләрдә «Аллаһның улы» тәгъбире башка христианнарны белдерү өчен дә кулланыла. Мәсәлән, Гайсә галәйһис-сәләәм хәвариләренә: «Дошманнарыгызны яратыгыз һәм сезне эзәрлекләүчеләр өчен дога кылыгыз. Шулай эшләп, күктәге атагызның балалары булуыгызны күрсәтерсез!..» – дип мөрәҗәгать итә (Матфей Инҗиле, 5/44–45, 6/1; Лука Инҗиле, 6/35).

Хәзрәти Гайсәнең мондый сүзләре дә риваять кылына: «Татулык урнаштыручылар бәхетле, чөнки аларны Аллаһы балалары дип атарлар!» (Матфей Инҗиле, 5/9).

Христиан идеологиясенә «Аллаһ – ата» тәгъбире рәвешендә чагылган әлеге хак юлдан тайпылыш хаклыкны чит күзләрдән сакларга тиешле ялган япмасын ертып атарлык дәрәҗәдә ап-ачык. Икенче яктан караганда, христианнар бу гыйбарәне башка кешеләргә карата үзенә күрә бер өстенлек сәбәбе буларак искә ала. Ләкин Аллаһ Тәгалә аларның мондый мөнәсәбәтенә карата болай ди:

وَقَالَتِ الْيَهُودُ وَالنَّصَارَى نَحْنُ أَبْنَاءُ اللَّهِ وَأَحِبَّاؤُهُ قُلْ فَلِمَ يُعَذِّبُكُم بِذُنُوبِكُم بَلْ أَنتُم بَشَرٌ مِّمَّنْ خَلَقَ يَغْفِرُ لِمَنْ يَشَاء وَيُعَذِّبُ مَنْ يَشَاء وَلِلَّهِ مُلْكُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَمَا بَيْنَهُمَا وَإِلَيْهِ الْمَصِيرُ

**«Яһүдиләр һәм насаралар: “Без – Аллаһның улларыбыз һәм Аның сөеклеләребез”, – диделәр. Әйт: “Ул ни өчен соң гөнаһларыгыз сәбәпле сезгә җәза бирә? Юк! Сез – Аның яралтканнары арасыннан кешеләрсез генә. Ул теләгәнен ярлыкар. Теләгәнен исә җәзаландырыр. Күкләрнең, җирнең һәм икесе арасындагыларның хакимлеге – Аллаһныкы гына. Кайту да Аңа гына”»** («әл-Маидә», 18).

Инҗилләрдәге каршылыклар, оксюмороннар арта бара:

* Хәзрәти Гайсә кулга алынган төндәге вакыйгаларны дүрт Инҗил дә төрлечә бәян итә. Ләкин бу мәсьәләдә дә берсендә сөйләнгәннәр икенчесенә каршы килә, бик зур аермалыклар һәм каршылыклар китереп чыгара (Матфей Инҗиле, 26/47–56; Марк Инҗиле, 14/13–52; Лука Инҗиле, 22/47–53).

* Хәзрәти Мәрьямнең ире булганлыгы турында әйтелгән Йосыф, Лука Инҗиленә күрә, Илийнең, ә Матфей китабына күрә, Ягъкубның улы дип санала (Лука Инҗиле, 3/23; Матфей Инҗиле, 1/16).

* Матфей, Марк һәм Лука Инҗилләрендә Хәзрәти Гайсәнең Хәзрәти Яхъя тарафыннан чукындырылганлыгы турында белдерелсә, Иоанн Инҗилендә чукындыру гамәле турында бер сүз дә әйтелми (Матфей Инҗиле, 3/17; Марк Инҗиле, 1/9–12; Лука Инҗиле, 3/21–22).

* Матфей, Марк һәм Лука Инҗилләренә күрә, Хәзрәти Гайсәнең төп иле Галилә дип аталса, Иоанн китабында Яһүдиййә дип күрсәтелә (Матфей Инҗиле, 13/54–58; Марк Инҗиле, 6/4; Лука Инҗиле, 6/29; Иоанн Инҗиле, 4/3, 43, 45).

* Матфей һәм Марк Инҗилләрендә Хәзрәти Гайсәнең Хәзрәти Яхъя төрмәгә ябылганнан соң эшкә керешүе әйтелә. Иоанн китабында исә төрмәгә хәтле үк үз вазифасын үти башлавы белдерелә (Матфей Инҗиле, 4/12–17; Марк Инҗиле, 1/14–15; Иоанн Инҗиле, 3/22–26, 4/1–3).

* Хәзрәти Гайсәнең әсир итеп алынуы, хөкемгә тартылуы, аркылы агачка тарттырылуы, кабергә куелуы, кабердән кубарылып терелүе һәм шәкертләренә күренүе, аннары күккә ашуы белән бәйле рәвештә, Инҗилләрдә бик күп төрле мәгълүмат табылуы да илаһи китап өчен аңлатып булмый торган парадокс хасил итә (Матфей Инҗиле, 27–28 нче баблар; Марк Инҗиле, 15–16 нчы баблар; Лука Инҗиле, 23–24 нче баблар; Иоанн Инҗиле, 19–20 нче баблар).

* Башка яктан карасак, шуны да күрербез: Гайсә галәйһис-сәләәм хачка кадакланган чакта, Матфей һәм Марк Инҗиленә күрә: «Аллаһым, Аллаһым! Ник миннән баш тарттың?» – дигән (Матфей Инҗиле, 27/46; Марк Инҗиле, 15/34). Пәйгамбәр һичкайчан андый сүзләрне әйтә алмас, чөнки бу Раббыга каршы баш күтәрү дигәнне күрсәтә. Бу вакыйга Хәзрәти Гайсәнең кешелек гөнаһларын ярлыкату өчен, үзен корбан итүе турында христианнар расларга маташкан фикер белән дә ярашмый.

* Гайсә галәйһис-сәләәм гадаралылар иленә килгәч, Матфейга күрә, җеннәр тозагына эләккән ике тиле белән очраша. Марк һәм Лука Инҗиленә күрә, бер тилене очрата (Матфей Инҗиле, 2/28; Марк Инҗиле, 5/1–2; Лука Инҗиле, 8/27–29).

* Яһүдиләр Гайсә галәйһис-сәләәмнән Юныс пәйгамбәр турында берәр дәлил күрсәтүен сорагач, Маркка күрә, «аларга һичбер дәлил дә күрсәтелмәячәк», дигән хәбәр бирелә, ә Матфей китабында «Юныс пәйгамбәр турында дәлил күрсәтеләчәге» белдерелә (Матфей Инҗиле, 12/38–41; Марк Инҗиле, 8/11–12).

Төрле тарихчылар, төрле мәгълүматлар һәм шулар арасында кысылып калган бер дин ул – бүгенге христианлык!..

**Христианнар фикеренчә, Хәзрәти Гайсәнең хачка кадаклану сәбәбе**

Христианнарга күрә, Адәм галәйһис-сәләәм белән Хәүва анабыз җәннәттә чагында тыелган җимешне ашап, бөтен кешелек өчен гөнаһ кылган (Дөньяның яратылышы, 3/24). Шунлыктан Аллаһ Тәгалә алар нәселеннән килгән балаларның һәркайсын утта яндырырга хөкем иткән. Ләкин Хәзрәти Гайсә, кешеләрне кызганганга күрә, хач өстенә тарттырып кадаклап асып куелу аша бөтен кешеләрнең гөнаһын ярлыкауны үз өстенә алган, үзен шуның өчен корбан иткән. Шул рәвешле кешеләр үзләренә мирас булып калган шул гөнаһтан котылган (Римлыларга хат, 3/23–26).

Мәсьәләнең асылы алай түгел икәнен Аллаһ Тәгалә Коръәни-Кәримдә аңлатып бирә:

وَبِكُفْرِهِمْ وَقَوْلِهِمْ عَلَى مَرْيَمَ بُهْتَانًا عَظِيمًا وَقَوْلِهِمْ إِنَّا قَتَلْنَا الْمَسِيحَ
عِيسَى ابْنَ مَرْيَمَ رَسُولَ اللَّهِ وَمَا قَتَلُوهُ وَمَا صَلَبُوهُ وَلَكِن شُبِّهَ لَهُمْ وَإِنَّ الَّذِينَ
اخْتَلَفُواْ فِيهِ لَفِي شَكٍّ مِّنْهُ مَا لَهُم بِهِ مِنْ عِلْمٍ إِلَّا اتِّبَاعَ الظَّنِّ وَمَا قَتَلُوهُ يَقِينًا

**«Янә аларның инкяр итүләре һәм Мәрьямгә зур яла якканнары өчен, янә аларның: "Һичшиксез, без Аллаһның рәсүле Мәрьям улы Гайсә Мәсихне үтердек", – дигәннәре өчен (ләгънәтләдек). Хәлбуки, алар аны үтермәделәр дә, кадакламадылар да. Ләкин алар өчен (Гайсә сурәтенә) охшатылды. Һичшиксез, бу хакта фикер каршылыгына төшкәннәр – аның хакында шик эчендәләр. Аларның бу хакта фаразга иярүдән башка бернинди гыйлемнәре юк. Һәм алар аны, шиксез, үтермәделәр»** («ән-Ниса», 156–157).

بَلْ رَّفَعَهُ اللَّهُ إِلَيْهِ وَكَانَ اللَّهُ عَزِيزًا حَكِيمًا

**«Аллаһ аны (Гайсәне) Үзе өстен кылган урынга күтәрде. Аллаһ – Бөек, Хикмәт иясе»** («ән-Ниса», 158).

Хакыйкать әнә шундый икән, илаһи газапны йомшарту өчен, Аллаһның үз улын аның ерак бабасы кылган бер хата аркасында үтерүенә ышану шулкадәр сәер ки, бу бит башка берәүнең гаебе өчен үлем белән түләү дигән сүз. Бер колының гөнаһын икенчесенә йөкләмәячәген белдереп куйган Җәнабел-Хак динендә мондый нәрсәгә инану булу бары ул диннең үзгәртелгәнлеге, бозылганлыгы белән генә аңлатыла ала. Өстәвенә, бүген христианнар, үз диннәренә өндәгәндә, Хәзрәти Гайсәнең үзен корбан итеп, кешеләрнең гөнаһлары өчен җавап биргәнлеген белдерүдән гыйбарәт күзгә бәрелеп торган гафиллек һәм кимчелек кебек, асылы тәмам бозылган христианлыкны нәфесне кызыктырырлык, үзенә җәлеп итәрлек рәвешкә китерергә тырышалар.

Ләкин шуны фикерләп карау һәм сорау тиеш: алар тыелган җимешнең ашалуын бөтен кешелек гөнаһы дип кабул иткәндә, үзләре кылган, кешелек абруена, кеше табигатенә һич килешмәгән никадәр явызлыкларга, Аллаһны кире кагу, буйсынмау кебек һәм башка хәтта тел белән әйтеп булмаслык күпме оятсызлыкларга рөхсәт бирә алалар соң?!. Тарихтагы бик күп мисаллар янында әле күптән түгел генә булган вакыйгалар – Босниядәге (Сребреница) кан коеш һәм башка шундыйларның бөтен дөнья күз алдында христианнар тарафыннан кылынуы, нәсара халкының мондый вәхшәтләр каршында сүзсез тамашачы гына булып калуы, Рим папасы һәм патриархия институтларының бу җинаятьләрне дәшми-нитми генә уздырып җибәрүе мәрхәмәт пәйгамбәре Хәзрәти Мәсих тарафдары булу фикере белән никадәр яраша соң? Үз балалары булмаганга күрә, йөкле хатыннарның карыннарын ярып, нәни сабыйларның каннарын ерткычларча актарганда, бер дә гөнаһ эшләмиләрмени?

Югыйсә Хәзрәти Гайсә, кешеләр арасында иң сайлап алынган, иң өстен дәрәҗә биләгән һәм күркәм әхлак тәрбияләр өчен килгән, Аллаһ каршында һәр тарафы белән илаһи ризалыкка ирешкән олуг пәйгамбәр булып тора. Димәк, Аллаһ Тәгалә сайлап алган һәм сөйгән бер үлүл-газыйм Рәсүлне, ата-бабасы кылган гөнаһ сәбәпле, хачка асу кебек газапка дучар ителүен күз алдына китерү дә (инану турында әйтеп тә торасы юк) мөмкин түгел. Бу – наданнар-

ча, денсезләрчә кылынган золымны Җәнабел-Хакка бәйләп карау, чып-чын логатьсезлек. Хәлбуки, Аллаһ пәйгамбәрләренә нинди зур дәрәҗәләр, хөрмәт һәм нигъмәтләр вәгъдә иткән. Тагын бер мөһим нәрсә: әгәр христаннар әйткәнчә, Гайсә галәйһис-сәләәм Алла булса, үзенә илаһлык сыйфаты тагылган затны берничә кеше кулыннан хачка асып куелырлык дәрәҗәдә көчсезлеккә, мескенлеккә төшүен күз алдына китереп буламы?

Икенче яктан караганда, Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәмнең башкалар өчен җәзаланып, иза чигүе мәсьәләсенә кагылышлы илаһи хөкемгә карасак, хакыйкать тулысынча ачыкланыр. Аллаһ Тәгалә әйтә:

مَنِ اهْتَدَى فَإِنَّمَا يَهْتَدِي لِنَفْسِهِ وَمَنْ ضَلَّ فَإِنَّمَا يَضِلُّ عَلَيْهَا وَلَا تَزِرُ
وَازِرَةٌ وِزْرَ أُخْرَى وَمَا كُنَّا مُعَذِّبِينَ حَتَّى نَبْعَثَ رَسُولًا

**«Кем дә кем туры юлдан китсә, ул үз файдасына гына һидәяткә ирешер. Кем дә кем адашса, ул үз зарарына адашыр. Бер генә (гөнаһ) йөртүче дә бүтән берәүнең йөген күтәрмәячәк. Без, бер рәсүл җибәрми торып, (һичкемгә) газап бирмәдек»** («әл-Исра», 15).

Аятьтә хәтта гөнаһлы затка да башкасының гөнаһы тагылмаячагы белдерелгәндә, гөнаһсыз бер кешегә бүтән берәүнең гөнаһы йөк итеп өелүен күздә тоткан фикер илаһи хакыйкатькә, хәтта кеше мантыйгына да каршы килә! Башка берәү кылган, үзе белән һич бәйләнеше булмаган гөнаһ өчен җавап тотуга кем ризалаша алыр икән?!

Хәзрәти Адәм галәйһис-сәләәмнең җәннәттә тыелган җимешкә кагылуы мәсьәләсенең хикмәтенә килгәндә, бу – аның кечкенә ялгышлыгы, ягъни махсус кылмаган хатасы. Бер яктан караганда ул, илаһи максатның үтәлүе өчен чынга ашкан, чөнки илаһи ният Адәм галәйһис-сәләәм белән Хәүва анабызның кеше өчен яралтылган җир йөзенә иңдерелүеннән, анда кеше нәселенең күбәюеннән һәм кыяматкәчә бу нәселнең сакланып калуыннан, җанын камилләштереп, Раббысына якынайтучыларны Адәм галәйһис-сәләәм килгән урын – җәннәткә кабат кайтарылуыннан, нәфесенә алданучыларны исә, шайтанның дуслары буларак, җәһәннәмгә озатудан гыйбарәт була.

Әлеге илаһи максатны Рәсүлүллаһ саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Әфәндебез болай аңлата:

*«Хәзрәти Адәм белән Хәзрәти Муса галәйһимәс-сәләм арасында бәхәс чыга. Хәзрәти Муса Хәзрәти Адәмгә: "Кылган гөнаһың аркасында син кешеләрне җәннәттән чыгаручы һәм аларны бәхетсезлеккә төшерүче түгелме?" – диде.*

*Хәзрәти Адәм исә Хәзрәти Мусага: "Син, Аллаһ рәсүллек бирү өчен сайлап алган һәм Аның сүзләрен ишетүгә лаек булган зат, мин яралтылганчы ук*

*Аллаһ миңа язган бер гамәл сәбәпле мине гаепләүдән тыел!.. (Бу –булмастай нәрсә!)" – дип җавап бирә».*

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бу сүзләрне дәвам итеп, болай ди: *«Хәзрәти Адәм Хәзрәти Мусаның авызын япты, сүз әйтмәслек хәлгә җиткерде»* (Бохари, «Кадәр», 11; Мөслим, «Кадәр», 13).

Икенче яктан караганда, Адәм галәйһис-сәләам һәм Хәүва анабыз, эшләгән гөнаһлары сәбәпле:

قَالَا رَبَّنَا ظَلَمْنَا أَنفُسَنَا وَإِنْ لَّمْ تَغْفِرْ لَنَا وَتَرْحَمْنَا لَنَكُونَنَّ مِنَ الْخَاسِرِينَ

**«И, Раббыбыз! Без үз-үзләребезгә золым иттек. Әгәр дә Син безне гафу итмәсәң һәм безгә мәрхәмәт итмәсәң, без зарар күргәннәрдән булырбыз»**, – дип («әл-Әгъраф», 23), тәүбә-истигъфар кылалар; нәтиҗәдә илаһи ярлыкауга, бихисап нигъмәтләргә лаек булалар. Илаһи мәгъфирәт белән гөнаһлары ярлыканган Хәзрәти Адәм галәйһис-сәләам, үзенә насыйп ителгәннәргә өстәп, Җәнабел-Хакка якынлыкта иң югары урын һәм колның гамәленә карамыйча, бары илаһи рәхмәт бәрабәренә генә бирелгән пәйгамбәрлек дәрәҗәсе белән хөрмәтләнгән.

Кыскасы, хәтта гафу ителмәгән бер гөнаһ та башкага йөкләнмәгән кебек, кичерелгән гөнаһның күчүе бөтенләй мөмкин түгел! Эчкерсез тәүбәләрдән соң ярлыкауга лаек булган гөнаһлар, Җәнабел-Хак рәхмәте белән, хәтта савапка да әйләнерләр. Аяти кәримәдә әйтелә:

إِلَّا مَنْ تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا فَأُوْلَئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا

**«Тик тәүбә иткән, иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр булмаса гына! Аларның начарлыкларын (гөнаһларын) Аллаһ күркәм нәрсәләр (саваплар) белән алмаштырачак. Аллаһ Гафу итүче, Рәхимле»** («әл-Фуркан», 70).

Аллаһ колларына Үз катыннан иңдергән илаһи китапларның һәркайсы «мөбин» (ап-ачык) сыйфатына ия. Иң соңгы китап булган Коръәни-Кәрим бу хикмәтне иң үтемле рәвештә күрсәтеп бирә. Анда «мөбин» сүзен бик күп урында аермачык итеп, басым ясап кабатлый-кабатлый, әлеге хакыйкатькә игътибар юнәлтелә. Ләкин Коръәни-Кәримнең җибәрелүенә сәбәпкә әйләнердәй дәрәҗәдә бозылган Инҗилләрдә мондый үзенчәлекне очрату мөмкин түгел.

Инҗилләрдәге бөтен каршылыклар аларның вәхи җимешеме-түгелме икәнлеге турында безгә артыгы белән мәгълүмат бирә. Һәр аңлы бәндә шуны аңлый: «Аллаһ» һәрнәрсәгә кодрәтле һәм һәртөрле начар сыйфатлардан азат булып, колларына шулкадәр буталчык һәм бик күп кимчелекләр тулып яткан

илаһи китап җибәрмәячәк, чөнки Ул – бернинди дә кимчелек хас булмаган «Сөбхан» зат.

Чынбарлык шундый ки, Гайсә галәйһис-сәләәмнән соң бик тиз бозылган христианлык кыска гына вакыт эчендә хак дин сыйфатын югалта һәм мәҗүсилек рәвешенә төренә. Мәҗүси мәдәниятләрдәге «хачка тартып асылган халык каһарманы» образы турыдан-туры Гайсә галәйһис-сәләәмгә карата кулланыла һәм бу вакыйга белән бәйле хач изге символга әйләндерелә, чөнки хач Европада христианлыкка кадәрге мәҗүсиләрдә очрый.

Христианлыкның тәүге чорларында гыйнвар аеның беренче көне яңа ел башы дип хисапланмый. Мәҗүси диннәрдә 24 декабрь белән 6 гыйнвар арасында төрле көннәрне билгеләп үтелгән Яңа ел бәйрәме христианнарга да йогынты ясый һәм Хәзрәти Гайсәнең тууы белән бәйләнгән бер фикер уйлап чыгарылып, 1 гыйнвардан башланган календарь барлыкка китерелә һәм бу көн бәйрәм итеп билгеләп үтелә башлый.

Борынгы Рим һәм грек король-императорларының бердәнбер максаты үлемнән соң аллага әйләнүдән гыйбарәт була. Бу төшенчә Гайсә галәйһис-сәләәмгә карата да кулланыла һәм ул Инҗилләрдә илаһи әкият герое шикелле итеп тасвирлана.

Кыскасы, Инҗилләрдә Аллаһ сүзе белән кеше сүзе, ялган фикерләр бер-берсенә керешкән, үрелеп киткән.

Элекке заманнардан бирле материалист булган яһүдиләр Гайсә галәйһис-сәләәм алып килгән тәүхид динне боза. Тынычлыкта, рәхәттә яшәр өчен, пәйгамбәрләренә һәрвакыт йөк булу, аларны үз мәнфәгатьләрендә куллану кебек чикне ашкан мөнәсәбәттәге бер кавем турында сүз бара, шунлыктан аларның үз-үзләрен болай тотуы гаять табигый.

Шуны онытмаска кирәк: Муса галәйһис-сәләәм белән Тәүратның һидәят юлын күрсәтә торган юламанлыгы һәм яктылыгы ни дәрәҗәдә булса, Гайсә галәйһис-сәләәм белән Инҗил дә, Хәзрәти Мөхәммәд галәйһис-саләтү вәссәләәм һәм Коръәни-Кәрим дә, хөкемнәре гамәлдә чакта, нәкъ шулкадәр үк һидәяткә алып баручы булып тора. Теге яки бу хөкемне канунлаштыручы китапларның, бер үк мәсьәләдә төрле вакытларда хөкемнәр чыгарса һәм иске хөкемнәрнең кулланылышын туктатса, гамәлдә булачагы, әлбәттә, иң соңгысы икәне бәхәссез. Әгәр Хәзрәти Муса галәйһис-сәләәм заманында Аңа иңдерелгәне түгел, әйтик, Хәзрәти Ибраһим галәйһис-сәләәмгә вәхи ителгәнгә иярү дәвам итсә, бу гамәлне Аллаһка итагать кылу дип атый алмыйбыз, киресенчә, ул буйсынмау, Аның кушканнарын үтәмәү дип бәяләнәчәк. Җәнабел-Хак, ахырзаман дине буларак, ислам динен җибәреп, аның хөкемнәренең кыяматкәчә сакланып калачагын Үзенең максаты итеп куйганлыктан, Коръәни-Кәрим – бүген хөкеме гамәлдә булган бердәнбер илаһи китап булып тора.

Бөтен илаһи китапларның төп чыганагы – бердәнбер Аллаһ Тәгалә. Барлык пәйгамбәрләр дә бер үк максат белән җибәрелә, үзләреннән әүвәлге хак пәйгамбәрләрне таный, раслый һәм соңыннан киләчәк пәйгамбәрләр турында сөенечле хәбәрне ирештерәләр. Ислам пәйгамбәре Хәзрәти Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә әүвәлге пәйгамбәрләрне хуплый, ләкин исламның иң соңгы дин, үзенең соңгы пәйгамбәр һәм Коръәни-Кәримнең соңгы илаһи китап икәнлеге турында хәбәр итә.

Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм:

*«Дөньяда да, ахирәттә дә Мәрьям улына (Гайсәгә) кешеләрнең иң якыны – Мин. Аның белән Минем арада пәйгамбәр юк. Пәйгамбәрләр барысы да – туганнар. Пәйгамбәрләр аналары башка, аталары бер булган ага-энеләр ул. Диннәре дә бер үк»*, – ди (Бохари, «Әнбия», 48; Мөслим, «Фәдаил», 143–145).

*«...Арагыздан кем (Ул дөньяда пәйда булачак ахыр заманда) Аның белән очраша, шул Миннән аңа сәлам әйтсен»* (Ибне Ханбәл, II, 298).

Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәм бүгенге чиркәүнең нәкъ киресе булган бик гади, тәкъва гомер кичергән. Аны башкалардан аерып торган сыйфатлар – нәфес һәм йөрәк тәрбиясе, ягъни дөньяның нәфсани теләк-омтылышларыннан баш тартып, рухи тормыш алып бару, югары әхлак, мәрхәмәт һәм үзара туганлыкны җәелдерү.

Тасаувыфның иң билгеле кагыйдәләреннән берсе булган «Аллаһ хакына сөю һәм Аның хакына нәфрәтләнү» мәсьәләсендә Гайсә галәйһис-сәләәм гә мондыйрак вәхи килә:

«Әгәр барлык җирдәгеләрнең һәм күктәгеләрнең гыйбадәтен кылсаң да, күңелеңдә Минем хакыма дуслык һәм минем хакыма дошманлык булмаса, бөтен бу гыйбадәтләрең Сиңа һичбер файда китермәс!»

Барлык гыйбадәтләребез һәм эш-гамәлләребезнең камиллеге рухи байлыгыбызга, күңел дөньябызга бәйле, ягъни сөюебезнең дә, нәфрәт тоюыбызның да Аллаһ хакына булуы таләп ителә.

Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәм : «Буйсынмаучыларга, гыйсьянчыларга дошманлык кылу аша Аллаһ белән дус булыгыз! Гыйсьянчылардан ерак булып, Аллаһка якынаегыз һәм, аларга нәфрәт тоеп, Аллаһның ризалыгын алыгыз!..» – дигән.

Йә, Раббы! Безгә хакны хак дип белеп, шуңа ябышырга, ялганны ялган дип белеп, аннан сакланырга, тыелырга һәм шул рәвешле ике дөньяда Үзеңнең ризалыгың бакчаларындагы нигъмәтләрең белән тәрбияләнгән изге колларыңнан булырга насыйп ит!

Амин!..

# ГОРБӘТ

Тәсаувыф юлы, гомумән алганда, горбәт[178], туган җиреңнән аерылу юлы булып тора, чөнки кешеләрнең бер-берсеннән аерылып китүе, ялгызлыгы нәтиҗәсендә Хак Тәгаләгә якынлык туа. Мәсәлән, Зәкәрийя галәйһис-сәләәм, аның улы Яхъя галәйһис-сәләәм һәм икетуганы Гайсә галәйһис-сәләәм тормышында әнә шундый горбәт хәле күзәтелә. Бу өч пәйгамбәрнең тирә-ягында аларга ианучыларның азлыгы, алар тәрбияләргә тырышкан кавемнәре тарафыннан икесенең үтерелүе, өченчесен дә үтерергә маташулары хәтта үз ватаннары һәм җәмәгатьләре эчендә дә аларга авыр ялгызлык, туган җиреңнән читтә яшәгәндәй читен гомер кичерергә туры килүен күрсәтә. Ләкин риясыз һәм фидакяр тормыш алып барып, ялгызлыклары, күргән авырлыклары нәтиҗәсендә, Хәзрәти Зәкәрийя һәм Хәзрәти Яхъя галәйһимәс-сәләм шәһид китеп; Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәм исә күккә күтәрелеп, Аллаһның үзләрен хөрмәтләвенә лаек булалар, «Аларга сәламем булсын!» дип искә ала торган пәйгамбәрләр дәрәҗәсенә ирешәләр.

Бу пәйгамбәрләргә хас горбәт төшенчәсенең хәдис-шәрифтә дә телгә алынуы игътибарны җәлеп итә. Аллаһ Рәсүле саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән:

*«Үзеңне бу дөньяда чит илдәге бер юлчы дип сана!»* (Бохари, «Рикак», 3; Тирмизи, «Зүһд», 25);

*«Ят җирдәгеләргә яхшы хәбәр булсын!»* (Мөслим, «Иман», 232).

Кеше табигатенә хас югары сыйфатларга омтылышларны әңгәмә, зикер, канәгатьлек һәм ихласлык белән үстереп, тәсаувыф өлгермәгән, белемсез кешедән «камил инсан» дәрәҗәсендәге шәхес формалаштыра. Кешеләрдә табигый теләк-омтылышлар һәм көч-сәләтләр төрле булганлыктан, тәсаувыф алымнарын кулланып, кешене әйберләр һәм вакыйгалар сереннән хәбәрдар кылу сыйфаты, һәр затта да бер үк нәтиҗә бирми. Ләкин кайбер омтылышларда бөтен кешеләр, хәтта дәрәҗәләре аерылып торса да, уртаклыкка ия. Мондый охшашлыкларның берсе исә – һәр бәндәнең үзе килгән җиргә, ягъни асыл ватанына кайту омтылышы.

Шунлыктан тәсаувыфның бер максаты да кешене «әләст бәзми»дә (җаннар галәмендә) Раббы белән бергә булган чагына кайтуга бәйле теләк, эзләнүләр, омтылышларын зикер белән ныгытып аң төпкеленнән чыгарудан гыйбарәт. Илаһи коллыкта камиллекне белдергән бу халәткә ирешү юлы аяти кәримәдә түбәндәгечә аңлатыла:

178. Горбәт – мосафирлык, туган ягыннан читтә яшәү; ялгызлык.

أَلَا بِذِكْرِ اللّٰهِ تَطْمَئِنُّ الْقُلُوبُ

**«...Күңелләр Аллаһны зикер итү белән тынычланмыймы (канәгатьлек ноктасына ирешер)?!»** («әр-Рәгъд», 28).

Бу халәт камил кешедә иң күркәм рәвештә чагылыш тапкан бер сыйфат булып тора, чөнки камил шәхес:

إِنَّا لِلّٰهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعونَ

**«...Һичшиксез, без – Аллаһныкылар һәм Аңа гына кайтачакбыз!»** («әл-Бәкара», 156) аятенең серенә-хикмәтенә төшенә.

Асылыңа кайту омтылышы мәхлуклар арасында өстен аң-зиһен бирелгән кешеләр һәм җеннәр арасында иң югары дәрәҗәгә ирешкәндә, хәсрәт һәм газап чыганагына әйләнер. Менә шулвакытта акылга ия һәр кол үзен ялгызлыкта, горбәттә хис итәр.

Чынлыкта горбәт мәхлукларның беренчел тамырыннан башланып, төрле сәхифәләрдән уза-уза, хәзерге урыныннан әүвәлге ватанына таба юлда төрле рәвешләр ала. Мәсәлән, адәм баласы әүвәл җаннар галәмендә була, аннары, бу урыннан китеп, ана карынына урнаша. Соңыннан дөньяга килә. Дөньялыкта да төрле урын алмашынуларга тарый ала. Аннан Бәрзах галәменә күченә. Һәм ниһаять, Раббысына кайта.

Ялгызлыкның бу тарафларын йөрәге белән тойган шагыйрь аның кайбер дәрәҗәләрен шушы шигырь юлларына салган:

«Бер басмадан кояш белән дәрья күренер,  
Бер басмадан һәм ике дөнья күренер,  
Соңгы басма исә күз булыр, китәр;  
Узган киләчәк тәмам төштә күренер!..»

Бөтен шушы әйтелгәннәр игътибарга алынганда, ялгызлыкның баскыч-баскыч, кат-кат булуы, бер-берсенә керешеп торуы аңлашыла. Аны бөтен баскычларны үтеп, үзебез килгән тәүге урынга, ягъни Раббыбызга кайтып кына бетерергә мөмкин. Бу халәткә бәйле рәвештә, җанны җәфалаган ялгызлык аркасындагы иң тирән һәм иң зур сагышны Раббы белән кавышу аша басарга була. Мондый олуг сагышны һәм рухи газапны аңламыйча, авылыннан, шәһәреннән китеп бару сәбәпле дә бик нык сызланган кешеләрдә дә иң тирән һәм иң зур горбәт аң төпкелендә мәңге сакланып калыр. Әлеге җан газабын бары өстен зиһен ияләре булган әүлиялар гына тиешенчә төшенә, аңлый. Алар горбәт баскычларының авырлыкларына сабыр итеп, илаһи кавышу теләге белән янып гомер кичерер. Шуңа күрә Җүнәйди Багдади Хәзрәтләре тәсаувыфны:

«Хак Тәгаләнең, сине синең үзеңдә үтереп, Үзе белән сине терелтүе ул», – дип атый.

Бу халәт – иң күркәм рәвештә бәндәнең Раббы белән бергә булу серенә ирешеп, тирән мәхәббәт белән зикер кылуын дәвам итүдә чагылыш таба. Зикер телнең Хак Тәгаләне исемен кабатлап торуы гына түгел, Аллаһ Җәллә Җәләлүһү сыйфатлары чагылышын аң белән төшенеп, бу исем-сыйфатларның йөрәккә кереп урнашуы ул.

Даими зикер белән шундый дәрәҗәгә ирешеп була ки, зикернең асылы кешенең яратылыш максаты белән берләшә, бәндә зикергә күнегә. Зикернең чын асылы аваз, сүз һәм тавышка бәйле түгел. Йөрәкнең җәүһәре, төп үзәге Раббыга бирелгәнгә күрә, пакьләнеп үзе дә күркәм сүзгә әйләнер, йомшар. Зикер һәм йөрәк шул рәвешле матдилектән арынгач, бер-берсе белән тәңгәлләшә, берләшә, чын тәүхиди иманга ирешә. Йөрәк анда бушлыкка эләгә, һәрнәрсәдән арына. Зикер ителә торган Җәнабел-Хактан кала бөтен нәрсә җуела, чөнки йөрәк бу дәрәҗәдә илаһи исем-сыйфатлар чынга аша торган үзәккә әверелә һәм кояш нурларын бергә туплаган линза яктылык төшкән урынны көйдергән-яндырган кебек, бөтен нәрсә юк ителә, яндырып бетерелә. Бу – юклык халәте, фани нәрсәләрнең аннан юкка чыгып, бакыйлары гына калган урын, иминлек, тынычлыкка ирешү.

Дөньялыктагы ялгызлыктан, җанга ят җирдән котылу һәм кавышу шатлыгы Мәүләна Җәләлетдин Руми Хәзрәтләрен үлемне туй төне буларак тасвирларга этәрә.

Аллаһ дусларының иң мөһим сыйфатларыннан берсе – шушы горбәт җир булган дөньяда бик зур сагыш утында янулары һәм чын үлемсезлеккә ирешүләре. Хәзрәти Мәүләна әлеге яну-көюнең хәтта үлем белән дә тынычлана алмаячагын бер бәетендә болай дип белдерә:

«Вафатымнан соң каберемне ач һәм үзәгемдәге ут сәбәпле кәфенемнән ничек төтен чыкканын күр!»

Үлем түшәгендә ятуына карамастан, йөзе шатлык белән балкыганын күреп, Хак Тәгаләне сөйгән затларның берсеннән: «Үлем ишек шакыганда, ничек шулай көлеп ята аласың?» – дип сорыйлар. Гашыйк бәндә болай дип җавап бирә: «Хәзер бөтен тәнем иренгә әйләнеп елмая! Ә бу мизгелдә иреннәрем башкача көлә!..»

Төн күбәләге яктылыкка тартыла. Яктылыкка омтылышы, аның тирәсендә әйләнеп йөрүе белән ул гади күбәләкләрдән аерылып тора. Яктылык чыганагын тапкач, мондый күбәләк транс хәленә керә, үз ихтыярына буйсынмый башлый. Ахыр чиктә яктылык чыганагына атылып, тәнен яндыра, шул рәвешле ул, теләгенә ирешеп, яктылык белән кушыла, анда эреп юкка чыга.

Хәзрәти Мәүләна дә: «Гәүдәне яндырмый торып, илаһи гашыйклык һәм мәхәббәт ләззәтенә ирешү мөмкин түгел!» – дигән.

Мансур әл-Халлаҗ да, үзе кичергән тирән рухи мохтаҗлык аркасында, үлемне сагынуын белдерә: «Минем терелүем, тормышым, кавышуым – үлемемдә!»

Менә шундый рухи күренешләргә күрә, горбәт ул –

Яралтучыдан аерылу;

Йөрәктә янып торган ут:

Сагыш утында яну-көю;

Ялгызлык.

Бу исә кешенең илаһи сәфәрдә булуы белән бәйле. Ул бу сәфәрен «әләст бәзми»дән башлый, аннары горбәт иле булган бу дөньяга җибәрелә. Хөр җаны тәннең әсирлегенә эләгә, биш тойгының әмерләрен үтәргә мәҗбүр ителә. Тик асыл тамырыннан аерылуы сәбәпле, анда үзе килгән дөньяга карата сагыш тойгысы һәм шунда омтылыш барлыкка килә. Ирешкән дәрәҗәсе, узган юлына нисбәтле рәвештә аң-зиһене дә сафлана барып, әлеге сагыш көчәя һәм иң төп ватанына, үзе килгән урынга кайту теләге арта. Бу исә кешенең һәрдаим горбәттә икәнлеген, үзе өчен ят җирдә гомер кичерүен белдерә.

Горбәтнең берничә төре бар.

Болар арасында пәйгамбәрләр һәм әүлиялар өчен бу дөнья горбәте эчендә тагын бер башка горбәт бар, ул исә дуслардан аерылу газабы белән янудан гыйбарәт. Әйтик, Аллаһка гыйбадәтләре тагын да артсын өчен, Ягъкуб галәйһис-сәләәм белән Йосыф галәйһис-сәләәм тәкъдиренә бер-берсеннән аерылышу, чит мәмләкәттә яшәргә мәҗбүр булу кебек авыр-авыр сынаулар языла. Шул рәвешле һәрдаим Хак Тәгаләгә юнәлсеннәр, Аның белән бергә булсыннар, Аннан башка нәрсәләр белән элемтәләрен өзсеннәр һәм югары дәрәҗәләргә ирешсеннәр өчен!..

Әнә шундый хикмәт сәбәпле пәйгамбәрләр, үз ватаннарын калдырып китеп, күпмедер вакыт читтә яшәргә мәҗбүр ителә, горбәт ачысын бөтен тарафтан авыз итә. Әйтик, Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә Таифтә горбәт авырлыкларын татый. Аны ташлар атып, канга батканчы кыйныйлар. Ләкин киң мәрхәмәте сәбәпле, искиткеч сабырлык һәм Аллаһ каршында ризалык үрнәге күрсәтеп, үзен таш атып кыйнаган Таиф халкына бәддога яудырасы урынга, Ул аларның һидәяткә ирешүләрен сорап, дога кыла. Шуннан соң Аллаһтан әҗер буларак, Аңа Мигъраҗ сәфәре кылу мөмкинлеге бирелә.

Горбәт кайгы, газап чигүне белдерә. Мәүләна Җәләлетдин Руми Хәзрәтләренең чиксез хикмәтле «Мәснәви»енең: «Тыңла, ни хакында хикәят кылам, Аерылышулардан зарлана-зарлана!» – дип башлануы, аерылышу һәм гор-

бәтнең көйдергеч утын әсәренә таҗ итеп кидерүе аның никадәр мөһим нәрсә икәненә игътибар юнәлтү белән бәйле.

Икенче яктан караганда, Хәзрәти Адәм галәйһис-сәләәм дә гомере башланган җир – җәннәттән чыгарыла һәм шул рәвешле Раббысы белән күрешеп тору мөмкинлегеннән мәхрүм ителә. Бу дөньяга җибәрелүе сәбәпле озын-озак еллар буе күз яшен түгә, сагыш-газаптан интегә, чөнки аның асыл ватаны җәннәт һәм Аллаһ каты була. Әлеге горбәттән бер өлеш аның нәселенә дә күчә. Димәк, сандугачның хәтта алтын читлектә дә «ватаным, ватаным!» дип елап сайравы турында уйлап караганда, кешенең бөек галәмнән түбән дәрәҗәдәге бер җиргә килүеннән елый-елый зарлануындагы хикмәт тагын да яхшырак аңлашыла төшә.

Хәзрәти Мәүләна горбәт турында нәй (шәрык халыклары курае) «авыз»ыннан сөйләтә:

«Нәй әйтә: “Камышлыктан алып чыкканнан бирле яңгыраган сыктавым җиһандагы һәркемне елатты”».

«Аерылышу бәгыремне кисәк-кисәк телде ки, гашыйклык кайгымны ничек аңлатыйм!»

«Асылыннан ерак китеп, аерылыша калса, һәркем даими кавышу мизгелен көтәр!»

«Мин һәр мәҗлестә яшь түгүче, изгеләрнең дә, бозыкларның да дустымын».

«Һәркем үзе бәясенә күрә, миңа дус булыр, уенымнан берәр нәрсә отып алырга теләр».

«Зар-елавым серемне ачып бирсә дә, бик күп йөрәкләрдә моны тоярлык нур юк!»

«Җан белән тән бер-берсеннән яшерен түгел. Ләкин җанны күрергә рөхсәт юк».

«Нәйнең тавышы ут булды, аны буш көй генә, дип уйлама! Мондый уты булмаганнар ни кызганыч!»

Хәзрәти Мәүләна робагыенда болай ди: «Нәйнең ниләр сөйләгәнен тыңла: Аллаһның яшерен серләрен ача ул. Йөзе саргайган, эче бушаган, башы киселгән, ул тулысы белән нәйче сулышына бирелгән. Шул хәлдә дә ул, телсез һәм сүзсез килеш, елый-елый: “Аллаһ… Аллаһ…” – ди». Чөнки нәй үзе туып-үскән камышлыктан кисеп алып кителә, ут ялкынында тотып, аның бәгырендә тишекләр ясала. Башына, аягына, хәтта буыннары арасына тимерчыбыклар һәм боҗралар тагыла, ягъни аңа богаулар салына, шуңа күрә корып-саргаеп йөзе сула.

Адәм баласы дә нәкъ шундый. Ул илаһи галәмдәге урыныннан шушы дөньяга китерелә һәм кеше дип теркәлеп, йөрәге аерылышу уты басып көйде-

реләә һәм сагыштан телем-телем теленә. Фәкать һәр кешегә хас бу чынбарлык, фикер һәм хис-тойгылар ярдәме белән күтәрелеп, камил бәндә дәрәҗәсенә ирешкәндә, тышка бәреп чыга. Ягъни андый сагыш йөрәктә моны тоярлык аң-зиһен нуры булганда үзен күрсәтер.

Җиһанда без күрә алган яки безгә күренмәгән барлык мәхлуклар Аллаһ Тәгалә исем-сыйфатларыннан бер өлешенең чагылышы булып тора. Кешедә исә илаһи исем-сыйфатларның барысы да бергә камил чагылыш тапкан. Кеше **«рухымнан аның эченә өргәч...»** («әл-Хиҗр», 29) аятенең серенә лаек булган. Шул сәбәпле ул – бер иҗат җимеше, ягъни күркәм сәнгать әсәре санала. Хак Тәгаләнең сәнгате, кодрәте, яралту куәте иң камил рәвештә кешедә чагылган. Шунлыктан адәм баласы рухи пычрактан, нәфес теләкләреннән арынса, тулы мәгънәсендә камиллеккә ирешә. Бер магнит тирәсендәге металл тузан кебек, кеше үзе килгән җиһанга таба бик көчле тартылу һәм сагыш тоя.

Бу күренеш кеше җанына, асылда ул Аллаһтан килгәнгә күрә, Хак Тәгалә белән кавышу омтылышы салынган булуыннан. Әлеге теләк-омтылышны чынга ашыру өчен, хак мәхәббәт таләп ителә. Мәхәббәт йөрәктәге ут булып, бу ут күңелдә Аллаһтан башка һични калдырмас, яндырып бетерер. Әнә шул ялкын аша бәндәдә үзе килгән урынга кире кайту теләге тышка чыгарыр, Раббысына карата тартылуы, Аның белән кавышу теләге артыр, сагышы көчәер.

Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ Билал радыйаллаһу ганһенең бу ят дөньядан котылып, Раббысына кавышу теләген бик матур сурәтли:

«Хәзрәти Билал, авырудан зәгыйфьләнеп, сүнеп барган айга охшап кала. Йөзенә үлем төсмере, үлем шәүләсе төшә. Хатыны аның бу хәлен күргәч: "Һай, нинди хәсрәт, тормышым, йортым җимерелә!" – дип кайгыра.

Билал исә аның сүзен бүлә: "Юк, юк! Алай димә!" һәм: "Хәзер шатлык-куаныч вакыты, өем салынды!" – дип әйтергә куша.

"Мин моңарчы дөньяның, ягъни Хак Тәгаләдән ерак бу ят җирдәге авыр тормышның эчендә идем!" – дип дәвам итә ул сүзен.

Боларны сөйләгән чакта, Билалның йөзендә нәркисләр, гөлчәчәкләр һәм лаләләр ачыла. Мөбарәк йөзе тагын да нурланып китә.

Хатыны исә, иренең сулышы сүлпәнләнеп, аның хәлсезләнә баруын күргәч: "И, күркәм холык, югары әхлак иясе булган Билал! Димәк, аерылышыр вакыт килде!.." – ди.

Билал исә: "Юк, юк! Очрашу, кавышу вакыты җитте. Инде бу сагыш, бу горбәт бетәчәк!" – ди.

Хатыны әйтте: "Син бу төндә ят җиргә китәсең, туганнарыңнан, балаларыңнан аерылып юкка чыгасың!.."

“Юк, бу төндә җаным горбәттән асыл ватанына кайта!” – ди Билал.

Хатыны Билалдан: “Синең йөзеңне инде башка күрә алмаячакбызмы?” – дип сорый.

Билал: “Син югарыга карасаң, Хак Тәгаләнең сөекле коллары арасында минем йөземне күрерсең! Сак бул, түбәндәгеләргә карама; анда пычрак дөньяның җирәнгеч йөзләре бар!” – ди.

Хатыны янә: “Һай, нинди хәсрәт, тормышым, йортым җимерелә!” – дип кайгысын белдерә.

Бу юлы Билал:”Син тәнгә түгел, җанга кара!.. Бала-чагам күп, йортым кысан иде. Аллаһ минем тәнемнән гыйбарәт өемне тагын да матуррак, тагын да күркәмрәк булсын өчен җимерде. Әгәр бу бәдән йортым җимерелмәсә, горбәтем бетмәячәк, асыл ватаныма, үзендә һич кимчелек булмаган матурлыклар дөньясына кайта, Хөсни Мотлак белән кавыша алмаячак идем!..” – ди».

Бөек Аллаһ дусларыннан шундый рухи халәттә яшәгән Газиз Мәхмүт Һүдайи Хәзрәтләре горбәт тормыштагы хис тойгыларын мондый шигъри юллар белән тасвирлый:

«Нишләтим дөньяны,
Миңа Аллаһым кирәк!
Кирәкмәс башкасы;
Миңа Аллаһым кирәк!..

Дөнья халкы – дөньяда,
Ахирәт халкы – ахирәттә.
Һәркайсы бер сөюдә;
Миңа Аллаһым кирәк!

Буш теләкне ку;
Хакны таба күр!
Һүдайинең сүзе бу:
Миңа Аллаһым кирәк!..»

Бу горбәт иленә килеп тә, дөньяның вакытлы теләкләренә бирешмичә, кавышу теләге белән янып гомер итүчеләрнең берсе Юныс Әмрә була. Ул бу галәмдә мәҗнүн кебек мәгъшукасыннан башкасына һич карамый һәм, фани җиһанга алданучыларга хәйран калып, горбәт илендә үзенең ялгызлыгын болай дип әйтеп биргән: «Мин аптырашта калдым килеп, Һичкем белмәс хәлемне! Үзем сөйлим, үзем тыңлыйм – Берәү дә белми телемне!»

Матди яктан кеше туфрактан ясалганга, ул туфракта яши, шуннан ризыклана. Ахырда исә туфракта югала, аның белән бербөтенгә әйләнеп, асылына, ягъни туфракка кайта. Шуңа күрә бу галәмнең камил атамасы «горбәт» булса да, аның вакытлылыгы сәбәпле «мосафирханә» дип йөртү киң таралган, чөнки

горбәттә һәрвакыт кире кайту шарты үтәлми. Моңа каршы исә мосафирлыктагы вакытлылык һәм иртәме-соңмы килгән урынга кире кайту фикере сәфәр башланган мизгелдән үк аңнан чыкмый.

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм беркөнне идәндәге чыпта өстендә йоклап китә һәм чыпта Аның мөбарәк тәнендә сырлар калдыра. Шуннан соң: «Чыпта өстенә берәр нәрсә җәйгән булса идек!» – дигән сәхабәләренә: *«Минем дөньялыкта ни эшем бар? Мин дөньялыкта сәфәре вакытында бер агач төбендә ышыкланып торган, аннары шуннан үтеп киткән бер юлчыга тиң»*, – дип әйтә (Ибне Мәҗә, «Зүһд», 3; Ибне Ханбәл, I, 391).

Беркөнне Хәзрәти Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм, кулын Хәзрәти Гомәр радыйаллаһу ганһенең иңбашына куеп, бу дөньяга вакытлы килүебезне белдерер өчен: *«Дөньяда йә читтән килгән бер кеше, йә бер юлчы кебек бул!»* – дип әйтә (Бохари, «Рикак», 3; Тирмизи, «Зүһд», 25).

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең горбәтне әнә шул рәвешле үтемле аңлатуы аркасындадыр, мөгаен, күпме бәгыре янган гашыйклар илаһи кавышу сәфәрендә үзләрен һәрвакыт чит җирләрдә яшәргә мәҗбүр бәндә итеп күрсәтә алалар. Аларның илаһи сөю белән сугарылган:

«Илаһым, җәннәт йортына керүчеләрдән кыл безне,

Шунда барып йөзеңне күрүчеләрдән кыл безне!» – дип ялварулары һәм Рәсүлүллаһтан мәхәббәт белән: «Күркәм йөзең белән сөендер, яндым ла, йә Рәсүлүллаһ!» – дип елый-елый сораулары сагыш утында янган бөтен йөрәкләрнең ихлас сүзләре булып яңгырый.

Соңгы чорның олуг шәехләреннән Мәхәммәд Әсгад Әрбили Хәзрәтләре шундый ук омтылыш-тартылу белән сөйгәненә ялвара:

«Йөзең нурыннан, дустым, күңел яктылык сорый, күзем аслам хакыннан, и табибым, тутыя[179] сорый! (И дустым! (Шушы караңгы горбәт иленә эләккән) күңелем йөзеңнең нурыннан бер яктылык сорый! И табибем! (Синнен башка яшәп калган шушы горбәттә) күзем синең юлыңның туфрагыннан бер сөрмә сорый!).

Юк күз яшеннән дәва, юк йөрәк зарыннан ярдәм, Минем авыр гөнаһым әнбия шаһы рәхмәтен сорый! (Күз яшьләрен туктатып, тынычландырып булмый, күңел зарына да ярдәм юк! (И сөеклем!) Минем (күтәреп йөри-йөри гаҗиз калган шушы) гөнаһ йөгем пәйгамбәрләр шаһының рәхмәтенә мохтаҗ, ягъни Синең шәфәгатеңне сорый!).

Гөл йөз-битләреңә хәйран калучылар, һич шөбһәсез, Синсез теләми мал-мөлкәт тә, дәрәҗә дә, зәвык та, сафа да! (Синең гөлдәй матур йөзеңә гашыйклар, һич шөбһәсез, (бары Сине генә теләрләр. Шунлыктан) Синсез

179. Тутыя – цинк, цинклы дару.

аларга мал-мөлкәт тә, зур дәрәҗәләр дә, ләззәтле татлар да, кәеф-сафа, шатлык та кирәкми!).

Бер мәртәбә шат булсын камил йөзең белән, фәкыйрь бәндәгез Әсгад, Сиңа фида булуны сорый! (И сөеклем! Сиңа корбан булырга теләгән шушы фәкыйрь колың Әсгад бер тапкыр (булса да, шул аң-хыял җитмәс) мөкәммәл йөзең белән (хөрмәтләнеп) сөенсә ни булыр!)».

Бер горбәт җире булган дөньяга килгәннән соң, һәр фани нәрсәнең, фани затның гомере үлем белән тәмамлана. Шуңа күрә дөньяга килү-китүнең вакытлы күренеш икәнлеген аңлап, чит җирдәге бер мосафир кебек яшәүчеләр, илаһи әҗер-савапларга өметләнеп, дөньяның иза-җәфаларын, кайгы-сагыш тулы сынауларында уңышка ирешү өчен тырышлык куя. Алар горбәт тормышының кайчак куаныч, кайчак исә кайгы-хәсрәт рәвешендә чынга ашкан төрле күренешләре каршында сабырлык, буйсынучанлык, Аллаһка бирелгәнлек һәм ризалык үрнәге күрсәтеп гомер кичерә. Мондый бәхетле затларның үлемнәре чиксез рәхмәт ишекләрен ача торган бер кавышу, ягъни Раббы белән очрашуга әйләнә.

Горбәтнең соңгы хатирәсе булган кабер ташларыннан шулкадәр гыйбрәт алырга мөмкин. Аларның һәркайсының аерым бер теле бар, алар күпме гыйбрәтле хәлләрне сөйләп бирә ала. Мәсәлән, бер ана, бәби тапканда, игез балалары белән бергә вафат була. Мәснәвиләрне шәрехләгән шагыйрь Таһирүл-Мәүләви бу вакыйгадан бик тәэсирләнә. Ул вафат булган хатынның туганнарын эзләп таба һәм: «Мин вафат булган бу өч кешегә тәгъзия буларак, кабер ташы яздыртырга телим!» – дип, шушы дүртьюллыкны иҗат итә:

«Бер кабер ташы язуы

Дөньяда дәр-агушка[180] әҗәл бирмәде мөмкинлек,

Итте мине һәм-макбәр[181] ике сабыем белән.

Инде тотып дәсти ятиманәләреннән[182]

Килдем Сиңа, Раббым, ике үксез балам белән...»

Мәүләна Җәләлетдин Руми дә шул сәбәпле дөнья тормышын кайчак горбәт, кайчак сәфәр галәме буларак сурәтли. Бу тормышның бивафа, вакытлы һәм алдавычлы булуы аркасында, аңа бар җаннарын-тәннәрен бәйләп куючыларның хәсрәткә тарыячагын белдерә. Мәүләна Хәзрәтләре дөньяның вакытлылыгы ягына басым ясап, аны кайчак мосафирханәгә тиңли. Хәтта җанның да тәндә вакытлылыгы сәбәпле бер мосафирлык халәтен кичерүе турында телгә ала.

180. Дәр-агуш – кочаклашу, кочаклау.
181. Һәм-макбәр – бер кабердә булу.
182. Дәсти ятиманәләреннән – ятим калган кулларыннан.

Шул рәвешле мосафирлыкның бер-берсе белән берләшеп китүе, бик күп тарафлары һәм рәвешләре күзәтелә. Бу галәмдә капма-каршы төшенчәләрнең бергә очрашуын, берләшүен дә искә алып, Мәүләна Җәләлетдин Руми Хәзрәтләре әлеге хакыйкатьне хикмәтле тел белән тасвирлый:

«И, яшь кеше! Бу тән – бер мосафирханә ул. Һәр иртә, синең кунакларың булган кайгы һәм шатлык анда йөгереп килеп җитәр».

«Белеп тор: бу мосафир муенымда калыр, дип уйлый күрмә! Ул юклыкка очар да китәр. Ягъни куаныч һәм хәсрәтнең мәңгелеге юк».

«Яшерен галәмнән ни килсә дә килсен, ул синең күңелеңнең бер кунагы булып тора. Ул һәрвакыт канәгать булырлык итеп яшә. Ягъни кайгы килгәндә, артык хәсрәтләнмә, куаныч вакытында да бик шатланма!»

«Кайгы-хәсрәт турында уй-фикерләр шатлык юлын бикли! Чынлыкта исә кайгы-хәсрәт башка шатлык-куаныч юлларын да ача».

«Уй-фикерләр һәм борчулар күңел йортыннан башка фикерләрне себереп чыгара – соңыннан йөрәккә яңа хәерле уйлар һәм шатлыклар килсен өчен!»

«Хәсрәт кулы күңел ботагыннан сары яфраклар коя – соңыннан бу ботаклардан бер-бер артлы яшел яфраклар атсын өчен!»

«Хәсрәт күңелдән ни генә чыгарса да, ни генә алып китсә дә, аның урынына тагын да хәерлесен китерер!»

Хәзерге заман шагыйрьләреннән Кадыйр Мысыроглу ватаныннан аерылырга туры килгән чагында язган «Горбәт» исемле бер шигырендә сагышны болай тасвирлый:

«Илемә түгел, Раббыма –
Тынычлык галәменә,
Кайтуга ук бетәр горбәт,
Котылгысыз нәтиҗә!..
Ләкин ул вакытка кадәр,
Мең дә бер төшү-чыгу бар!..»

………

Атаклы мәкаль-әйтем:
«Җитәр! Бетермә сулышыңны,
Аллаһ җитәр, бакыйлык – теләк!..»

Йә, Раббы! Безгә бу горбәт җирдә кавышу теләге белән янып яшәргә насыйп кыл! Безне йөзеңне күрәчәк изге колларың арасына керт!

Амин!..

***Хәзрәти Зәкәрийя, Хәзрәти Яхъя галәйһис-сәләәм***




***Хәзрәти Гайсә галәйһис-сәләәм***



# ЭЧТӘЛЕК

**СҮЗ БАШЫ** ........ **7**

**КЕРЕШ** ........ **13**

Коръәни-Кәрим кыйссаларының әһәмияте ........ 13

Коръәни-Кәрим кыйссаларының максаты ........ 14

Коръәни-Кәрим кыйссаларының үзенчәлекләре ........ 17

Кабатлауларның хикмәте ........ 17

Коръәни-Кәримдә пәйгамбәрләр һәм алар турында кыйссалар ........ 21

Коръәни-Кәримнең бөеклеге һәм Пәйгамбәребезнең фазыйләте ........ 25

**ХӘЗРӘТИ АДӘМ** ***галәйһиссәләм / 39***

Яралтылуыбызның төп сәбәп һәм хикмәтләре ........ 43

а) Мәгърифәтуллаһ. ........ 44

б) Мәхәббәт. ........ 45

Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмнең яралтылуы ........ 48

Фәрештәләрнең Җәнабел-Хакка сорау бирү хикмәте ........ 50

1. Туфрак этабы. ........ 54

2. Юеш балчык этабы. ........ 54

3. Ябышкак юеш балчык этабы. ........ 55

4. Һавада кипкән дымлы балчык этабы. ........ 55

5. Бер рәвешкә кергән балчык этабы. ........ 55

6. Утта яндырылган балчык этабы. ........ 55

Җан кертелү (өрелү) ........ 57

Җанның биш чоры ........ 59

1. Юклык чоры. ........ 59

2. Җаннар галәменең барлыкка килү чоры ........ 59

3. Кеше тәненә кертелү чоры. ........ 59

4. Тәннән аерылу чоры. ........ 60

5. Кабат тәннәргә кайтарылу чоры. ........ 60

Фәрештәләрнең Хәзрәти Адәм галәйһиссәләмгә сәҗдә кылуы ........ 68

Хәзрәти Хәүва анабызның яралтылуы .............................................................. 78
Җәннәт тормышы............................................................................................... 81
Җәннәттән җиргә төшерелү ............................................................................ 81
Кешедәге рухи халәтнең зәгыйфь урыннары ............................................ 86
1. Кеше бик залим һәм надан. ..................................................................... 86
2. Кеше ашыгучан була. ............................................................................... 89
3. Кеше үз мәнфәгатен кайгыртучан. ......................................................... 91
4. Кеше Аллаһка карата рәхмәтсез. ............................................................ 92
5. Кеше саран һәм ачкүзле. .......................................................................... 94
6. Кеше көнче һәм хөсетле. ......................................................................... 95
7. Кеше зәгыйфь итеп яралтылган. ............................................................. 96
Хәзрәти Адәм белән Хәүва анабызның гафу ителүе .................................... 101
Җир йөзендә беренче җинаять ....................................................................... 102
Хәзрәти Адәм галәйһиссәләм кыйссасыннан алынырга тиешле сабаклар ......................................................................................... 106
ТӘҮБӘ ҺӘМ ИСТИГЪФАР............................................................................. 108

## ХӘЗРӘТИ ИДРИС *галәйһиссәләм / 121*

ЙӨРӘК ҺӘМ АНЫҢ СЕРЛӘРЕ ...................................................................... 124
1. Мөһерле һәм бикле йөрәкләр. ................................................................. 126
2. Авыру йөрәкләр. ....................................................................................... 128
3. Гафил йөрәкләр. ........................................................................................ 130
а) Хәләл ризык. .......................................................................................... 131
б) Коръәни-Кәримне аңлап-фикерләп уку. ............................................... 132
в) Гыйбадәтләрне хошуг белән үтәү. ........................................................ 133
г) Аллаһны зикер итүдә дәвамлылык. ....................................................... 135
д) Төннәрне уяу уздыру. ............................................................................. 136
е) Изге һәм тугры кешеләр белән бергә булу. .......................................... 138
4. Зикер итүче йөрәкләр. ............................................................................. 139
5. Тере (сәламәт) йөрәкләр. ......................................................................... 144

## ХӘЗРӘТИ НУХ *галәйһиссәләм / 149*

Нух галәйһиссәләм кавеменең үзенчәлекләре ........ 150
Озын-озак тәблигъ еллары ........ 153
Бәдбәхет кавемнең газап соравы ........ 158
Туфан – җибәрелгән газап ........ 161
Суларның чигенүе ........ 164
Гашура көне ........ 167
Нух кавеменең төп һәлак ителү сәбәпләре ........ 169
Нух галәйһиссәләмнең кайбер сыйфатлары ........ 170
САБЫРЛЫК ........ 172

## ХӘЗРӘТИ ҺУД *галәйһиссәләм / 181*

Гад кавеме ........ 181
Гыйбрәтле илаһи кисәтүләр ........ 185
Пыран-заран китергән давыл ........ 187
Хәзрәти Һуд галәйһиссәләмнең могҗизалары ........ 190

## ХӘЗРӘТИ САЛИХ *галәйһиссәләм / 195*

Сәмуд кавеме ........ 195
Дәгъватка керешү ........ 196
Дөя могҗизасы ........ 200
Рәхмәтсезлек ........ 201
Азгын кавемнең куркыныч тавыш һәм зилзилә белән һәлак ителүе ........ 204
Сәмуд кавеменең юк ителү сәбәпләре ........ 207
КАВЕМНӘРНЕҢ ҺӘЛАК ИТЕЛҮЕ ........ 208

## ХӘЗРӘТИ ИБРАҺИМ *галәйһиссәләм / 221*

Раббым – Аллаһ ........ 223
Тәүхидкә өндәү ........ 225
Хәзрәти Ибраһимнең потларны җимерүе ........ 227
Хәзрәти Ибраһимнең утка ыргытылуы ........ 228
Утның гөлбакчага әйләндерелүе ........ 231
Ибраһим галәйһиссәләмнең һиҗрәте ........ 233

Нәмрудның һәм Кәлдани кабиләсенең һәлак ителүе ..... 235
Кошларның терелүе ..... 236
Ибраһим галәйһиссәләмнең Һаҗәр анабыз белән гаилә коруы ..... 239
Корбан сынавы ..... 241
Исхак галәйһиссәләмнең тууы ..... 248
Ибраһим галәйһиссәләмнең Хәзрәти Исмәгыйльне зиярәт кылуы ..... 251
Кәгъбәне төзү ..... 253
Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһимәс-сәләмнең тәүге хаҗы һәм кешеләрне хаҗга чакыруы ..... 256
Ибраһим галәйһиссәләмнең дога-ялварулары ..... 256
Хәзрәти Ибраһим нәсыйхәтләре ..... 268

**ХӘЗРӘТИ ИСМӘГЫЙЛЬ** ***галәйһиссәләм / 263***

Могҗизалары ..... 264

**ХӘЗРӘТИ ИСХАК** ***галәйһиссәләм / 267***

Төрле риваятьләргә күрә, Исхак галәйһиссәләмнең могҗизалары ..... 268
АЛЛАҺКА ТӘВӘККӘЛ КЫЛУ, БУЙСЫНУЧАНЛЫК ҺӘМ ХАҖ ..... 269

**ХӘЗРӘТИ ЛУТ** ***галәйһиссәләм / 277***

Содом халкы ..... 277
Куркыныч тавыш һәм киптерелгән ташлар яву ..... 279
Лут галәйһиссәләмнең хатыннары һәм балалары ..... 282
Лут кавемендәге яман гамәлләр һәм һәлак ителү сәбәпләре ..... 283
Помпей халкының һәлак ителүе ..... 285
ӘХЛАК КҮРКӘМЛЕГЕ ҺӘМ НӘСЕЛНЕ САКЛАУ ..... 287
Нәселне саклау ..... 288

**ХӘЗРӘТИ ЗӨЛКӘРНӘЙН** ***галәйһис-сәләәм / 293***

Зөлкәрнәйн галәйһис-сәләәмнең мөһим сыйфатлары ..... 294
Тәүхидкә өндәү өчен сәфәрләре ..... 295
Яәҗүҗ һәм Мәәҗүҗ кавеме ..... 298
Хәзрәти Зөлкәрнәйннең гыйбрәтле һәм хикмәтле кыйссаларыннан ..... 301
ҖИҺАД ҺӘМ ӘМРИ БИЛ-МӘГЪРУФ (яхшылыкка өндәү) ..... 303

**ХӘЗРӘТИ ЯГЪКУБ** ***галәйһис-сәләам / 315***

**ХӘЗРӘТИ ЙОСЫФ** ***Галәйһис-сәләам / 315***

Йосыф кыйссасы – кыйссаларның иң матуры ............ 317
Хәзрәти Йосыфның төше ............ 321
Төшләр өч төрле була ............ 322
Көнчелек – йөрәкне үтерә торган ут ............ 323
Бәлаләр авыздан чыккан сүзгә бәйле ............ 327
Туганнарның хыянәте ............ 328
Хәзрәти Йосыфның коега ыргытылуы ............ 329
Иң матур сабырлык ............ 332
Хәзрәти Йосыфның коедан чыгарылып, сатып җибәрелүе ............ 333
Хәзрәти Йосыф һәм Зөләйха ............ 336
Йосыфны күргән хатыннар кулын кисә ............ 339
Зиндан ............ 341
Хәзрәти Йосыфның төш юравы ............ 343
Мисыр патшасының төше ............ 345
Дарван кыйссасы ............ 347
Хәзрәти Йосыфның зирәклеге ............ 349
Аллаһ колны солтан итә ............ 351
Зөләйха белән өйләнешүе ............ 354
Туганнарының азык-төлеккә килүе һәм
Хәзрәти Йосыфның күркәм планы ............ 355
Синең кардәшең – Йосыф мин! ............ 358
Хәзрәти Йосыфның Бүньяминне алып калуы ............ 359
Әҗер-савап ишекләрен ачкан җәфалар ............ 363
Аллаһның рәхмәтеннән өмет өзелмәс ............ 364
Дастаннарда мактарлык гафу-кичерү ............ 366
Күлмәгемне әтиемнең күзләренә сөртегез ............ 368
Хәзрәти Ягъкубның күзләре ачылу ............ 369
Кавышу һәм чынга ашкан төш ............ 371
«Йосыф» сүрәсенең ахыргы аятьләре ............ 373
РАБЫТА, ИСТИГАНӘ ҺӘМ ИСТИГАЗӘ ............ 376
Рухи халәт чагылышлары ............ 377

1. Караш (күңел күзе)........ 378
2. Сүз........ 378
3. Әңгәмә........ 378
4. Калган ризык белән бәрәкәтләнү........ 378
5. Рухи халәтнең предмет аша күчерелүе........ 379
Рабыта-и Мәүт........ 385

**ХӘЗРӘТИ ШӨГАЕБ** ***галәйһис-сәләәм / 391***

Мәдйәнлеләр........ 391
Соңгы кисәтүләр........ 396
Өстән килгән куркыныч тавыш........ 399
Әйкәлеләр........ 400
Күктән төшкән газап – көйдерүче ялкын........ 402
Һәлак ителгәннән соң........ 403

**ХӘЗРӘТИ МУСА** ***галәйһис-сәләәм / 409***

**ХӘЗРӘТИ ХАРУН** ***галәйһис-сәләәм / 409***

Фиргавенне куркыткан төш........ 410
Хәзрәти Муса Фиргавен сараенда........ 412
Кыптыйның үлеме........ 415
Мисырдан Мәдйәнгә........ 417
Шөгаеб галәйһис-сәләәмнең Хәзрәти Мусаны үз янына чакыруы........ 419
Муса галәйһис-сәләәмнең Сафура белән өйләнешүе........ 422
Муса галәйһис-сәләәм таягы........ 423
Мәдйәннән Мисырга бару һәм Тува үзәнлеге........ 424
Ике бөек могҗиза белән бирелгән пәйгамбәрлек........ 426
Ахмак Фиргавен........ 435
Могҗиза белән сихернең ярышы........ 437
Сихерчеләрнең сәҗдәгә каплануы........ 440
Машыйта хатын........ 445
Асия анабызның шәһид китүе........ 446
Манара........ 447
Могҗизалар........ 449

1. Туфан ........ 449
2. Саранча ........ 449
3. Бет-борчалар ........ 450
4. Гөберле бакалар ........ 450
5. Кан ........ 450
Фиргавеннең хәйләле мескенләнүе ........ 453
Мисырдан китү ........ 454
Кызыл диңгез – иминлек һәм һәлакәт диңгезе ........ 456
Фиргавеннең иманы кабул ителми ........ 458
Кызыл диңгезне кичкәч ........ 459
Әриха җирлегендә Амалика кавеменә каршы сугыш белән сыналу һәм Тих чүле ........ 461
Тәүрат иңдерелү ........ 465
Кырык санының хикмәте ........ 467
Муса галәйһис-сәләәмнең Аллаһны күрергә теләве ........ 468
Сина тавындагы сөйләшү ........ 472
Алтын бозау ........ 473
Сыерны корбан итеп чалу ........ 481
Бу кыйссадагы гыйбрәтләр ........ 483
Пәйгамбәребезнең Мигъраҗда Хәзрәти Муса белән очрашуы ........ 484
Карун ........ 485
Шакшы яла ........ 487
Муса галәйһис-сәләәм белән Хозыр галәйһис-сәләәм ........ 489
Өч изге бәндә ........ 497
Муса галәйһис-сәләәмнең җәннәттәге күршесе ........ 499
Муса галәйһис-сәләәмнең фазыйләтләре, килеш-килбәте һәм сыйфатлары ........ 500
БҮГЕНГЕ ИУДАИЗМ ........ 502
Иудаизмда тәңрене танып белү ........ 502
Тәүрат ........ 505
Талмуд ........ 506
Пәйгамбәрләрне кабул итү ........ 507
Ахирәт төшенчәсе ........ 509

**ХӘЗРӘТИ ДАВЫТ** ***галәйһис-сәләәм / 515***

Талут, Җалут һәм табут .......... 515
Сынау .......... 517
Хәзрәти Давыт һәм җиңү .......... 519
Давыт галәйһис-сәләәмнең сыналуы .......... 524
Әсхабе Сәбт вакыйгасы .......... 526
Хәзрәти Давыттан калган истәлек: «Давыт уразасы» .......... 529
Давыт галәйһис-сәләәмнең фазыйләтләре .......... 530
Давыт галәйһис-сәләәмнең үлеме .......... 530
Зәбур һәм аның эчтәлеге .......... 531
ИҢ МАТУР СҮЗНЕ МАТУР ИТЕП УКУ .......... 533

**ХӘЗРӘТИ СӨЛӘЙМАН** ***галәйһис-сәләәм / 551***

Сөләйман галәйһис-сәләәмнең ат яратуы .......... 558
Сөләйман галәйһис-сәләәмнең сынауга тотылуы .......... 559
Бәйтүл-Макдисне төзү .......... 562
Сөләйман галәйһис-сәләәм, һөдһөд кошы һәм Бәлкыйс .......... 565
Кәрамәт .......... 570
Сөләйман галәйһис-сәләәмнең үлеме .......... 572
Хакимлек һәм кече күңеллелек .......... 574
Хәзрәти Сөләйманнан соң .......... 575
Һарут белән Марут кыйссасы .......... 575
Рәсүлүллаһ Әфәндебезнең Хәзрәти Сөләйманнан өстенлеге .......... 577
БАР МӨЛКӘТ – АЛЛАҺНЫКЫ .......... 579
Инфак әдәбе .......... 587

**ХӘЗРӘТИ ГОЗӘЕР** ***галәйһис-сәләәм / 595***

ҮЛГӘННӘН СОҢ ТЕРЕЛҮ .......... 598
Әсхабе Кәһф .......... 598

**ХӘЗРӘТИ ӘЙЮБ** ***галәйһис-сәләәм / 615***

Сынау, сабырлык һәм әҗер-савап .......... 616
Авырудан котылу .......... 621

Рахмә хатынның хезмәте өчен әҗере ........ 622
РИЗАЛЫК ........ 624

**ХӘЗРӘТИ ЮНЫС** ***галәйһис-сәләәм / 639***

Ниневиялеләр ........ 639
Иман, тәүбә һәм гафу итү ........ 640
Хәзрәти Юныс Ниневиядән киткәч... ........ 641
Юныс галәйһис-сәләәм кыйссасыннан алынырга тиешле сабаклар: ........ 645

**ХӘЗРӘТИ ИЛЬЯС** ***галәйһис-сәләәм / 649***

**ХӘЗРӘТИ ӘЛЬЯСАГ** ***галәйһис-сәләәм / 655***

**ХӘЗРӘТИ ЗӨЛКИФЕЛ** ***галәйһис-сәләәм / 659***

**ХӘЗРӘТИ ЛОКМАН ХӘКИМ** ***галәйһис-сәләәм / 663***

ХӘМЕД ҺӘМ ШӨКЕР ........ 671

**ХӘЗРӘТИ ЗӘКӘРИЙЯ** ***галәйһис-сәләәм / 683***

**ХӘЗРӘТИ ЯХЪЯ** ***галәйһис-сәләәм / 683***

**ХӘЗРӘТИ ГАЙСӘ** ***галәйһис-сәләәм / 683***

Зәкәрийя галәйһис-сәләәм ........ 684
Яхъя галәйһис-сәләәм ........ 684
Гайсә галәйһис-сәләәм ........ 689
Юктан бар итүче атасыз да яралтыр! ........ 692
Хәзрәти Гайсәнең пәйгамбәрлеге ........ 699
Күктән табын төшү (Маидә) ........ 703
Хәвариләрнең һәм Гайсә галәйһис-сәләәмнең Нусайбингә китүе ........ 706
Хәбибән-Нәҗҗар ........ 707
Гайсә галәйһис-сәләәмнең күккә күтәрелүе ........ 710
Гайсә галәйһис-сәләәм күккә ашканнан соң ........ 712
Инҗилләрнең күп язылу сәбәбе ........ 717
Гайсә галәйһис-сәләәмнең күктән иңдерелүе ........ 717
Гайсә галәйһис-сәләәмнең могҗизалары ........ 718
БҮГЕНГЕ ХРИСТИАНЛЫК ........ 721

Тәслискә (Өч тәңрегә) ышану ............ 729
Дүрт Инҗилнең үзенчәлекләре ............ 739
Матфей ............ 741
Марк ............ 742
Лука ............ 742
Иоанн ............ 743
Дүрт Инҗилдәге каршылыклар ............ 744
Христианнар фикеренчә, Хәзрәти Гайсәнең хачка кадаклану сәбәбе ............ 748
**ГОРБӘТ ............ 754**
**ЭЧТӘЛЕК ............ 765**

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

................................................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................

........................................................................................................................